# Аяз Гыйләҗев

Фәнни-популяр җыентык

Казан
«Җыен» нәшрияты
2023

ББК 83(2Рос=Тат)
Г92

*Китап «Татнефть» Компаниясенең матди ярдәме белән нәшер ителде*

*«Шәхесләребез» сериясенә нигез салучы*
Татарстан Фәннәр академиясе академигы, тарих фәннәре докторы
М.Г. Госманов

*Редколлегия:*
Р.И. Вәлиев (җаваплы мөхәррир), М.Б. Галиев, Р.К. Гатауллин
(Рәдиф Гаташ), Х.Й. Миңнегулов, Ф.М. Рәфыйков, И.Г. Һадиев

*Фәнни мөхәррир*
Искәндәр Гыйләҗев,
тарих фәннәре докторы

*Төзүчесе*
Миләүшә Хәбетдинова,
филология фәннәре кандидаты

**Г92** **Аяз Гыйләҗев** : фәнни-популяр җыентык / Төз. Хәбетдинова М. М. – Казан: Җыен, 2023. – 672 б. : илл.– («Шәхесләребез» сериясе)

ISBN 978-5-902783-65-7

Җыентыкта Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев (1928–2002) турында истәлекләр белән бергә үзенең автобиографик язмалары, тәнкыйди-публицистик мәкаләләре, әңгәмәләре, фоторәсемнәр урын алдылар. Шәхси архивында сакланган хатлар, көндәлекләр, бәяләмәләр, документлар XX гасырның иҗтимагый аң-фикер үсешен барлауда да зур әһәмияткә ия. Китапка язучы образын яктырткан каләмдәшләренең әсәрләре кертелде. Басма хронологик һәм жанр төрлелеге принципларына нигезләнеп төзелде.

ББК 83(2Рос=Тат)

ISBN 978-5-902783-65-7

© «Җыен» фонды, 2023
© Хәбетдинова М. М., төзү, текст, иск. һәм аңлат. әзерл. 2023

## Кереш сүз

Кыю булырга тырышылган.
Намуслы булып калырга омтылганмын.
*Аяз Гыйләҗев*

Без югары технологияләр дәверендә яшибез. Әдәбиятны – Интернеттагы блоглар, кеше күңелен iPad һәм iPhone алыштырган, әдәби мәйданда графоманнар, sms-әдәбият вәкилләре ат уйната торган чор бу. Көнкүрешебезгә көннән-көн ныграк үтеп керә барган әлеге яңалыкларга каршы тора алырлык көч бар, билгеле. Ул да булса дөнья әдәбияты – Гомердан Тукайгача һәм хәзер дә үзенең даһилыгын, бөеклеген югалтмаган милли әдәбиятыбыз. Ходайга шөкер, ул яши, үсә һәм үзгәрә. Ф. Абрамов, В. Белов, В. Распутин, А. Солженицын, А. Гыйләҗев, Ә. Еники, М. Мәһдиев кебек бөек каләм ияләренең чордашлары һәм аннан соңгы буын, горурланып: «Әдәбият яши!» – дип әйтә ала. Әйе, асыл әдәбиятның үз укучысы, зәвыклы, таләпчән аудиториясе бар әле...

Кадерле укучы! Бүген сүзебез шул бөек язучыларның берсе булган А. Гыйләҗев хакында.

Татарстанның халык язучысы, Татарстан Республикасының Г. Тукай һәм РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт бүләкләре, Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге әдәби премиясе лауреаты, Татарстанның һәм Русиянең атказанган сәнгать эшлеклесе А. Гыйләҗевнең (1928–2002) иҗади мирасы хаклы рәвештә XX–XXI йөз татар мәдәниятенең иң кыйммәтле хәзинәсе санала, чөнки ул – әдәби-мәдәни дәверне яңарыш чорына алып кергән, милли үзаңны, фикер күтәрелешен әзерләгән, яшәү мәгънәсен милләткә хезмәттә күргән әдип. Аның дистә еллар дәвамында тудырылган гаҗәеп киңкырлы, күп катламлы, жанр

төрлелеге һәм тема ягыннан гаять бай әдәби иҗаты XX гасыр татар тормышының иҗади елъязмасы булып укыла, милли әдәбиятның гына түгел, дөнья әдәбияты үсешенең дә бер өлеше булып тора. Хаклы рәвештә әйтә алабыз: язучының бу уңышлары – тормышта һәм иҗатында үз кыйбласына тугры калуында. 1973 елда язылган «Үзем турында үзем» мәкаләсендә дә моны ачык күрәбез: «Тормыш агышыннан ычкынып төшеп калмаска кирәк. Барыбыз да шуңа омтылабыз. Тормыштан артта калмас өчен, аның хәрәкәтен генә түгел, үзгәрмәс кыйбласын да яхшы белергә кирәк. Туган иленә, халкыңа бирелгәнлек, туган теленә сүнмәс мәхәббәт – менә ул язучының үзгәрмәс кыйблалары! Тормыш шартлары, яшәү күренешләре көнләп-сәгатьләп үзгәреп торса да, бу бөек төшенчәләр мәңгелек, һәм шушы мәңгелеккә тугры кешеләр генә үзгәрешләрне халык белән бергә сиземли алалар». Әдәбият мәйданына нәкъ менә «җепшеклек» дәверендә аяк басканга, язучы һәрвакыт киләчәккә якты өмет белән яши. Хыялөметләре чынга ашмаса да, аның ихлас ышанычы укучы күңелен җылыта, баета, нурлы итә. Үз әсәрләрендә Идел-йортны данлаган әдип татар мәдәниятен тирәннән тоеп, белеп яза.

Укучы игътибарына бүген тәкъдим ителәчәк «Аяз Гыйләҗев» җыентыгына мемуар-автобиографик жанрга караган әсәрләр, язучының хатлары, көндәлекләре, әңгәмәләре, публицистик һәм тәнкыйть мәкаләләре кертелде. Әдипнең үз сүзләренә караганда, бу әсәрләрендә ул ачыктан-ачык һич үзгәрешсез тыелып калган фикерләрен, әйтергә теләп тә телен тешләп, туктап калган уйларын яза. Укучысына мөрәҗәгать итеп, А. Гыйләҗев болай ди: «Мин сезне күрәм, ә сез мине күрәсезме? Мин ич бу, мин! «Өч аршын»ны язган, «Җомга көн, кич белән...»дә Бибинур булып сезгә кычкырган татар баласы! Гомерем буе сезнең җәбер-җәфаларны аңларга тырышып, кайгы-хәсрәтегезне үземнеке итеп санап, тормышыгызны җиңеләйтергә, офыгыгызны киңәйтергә тырыштым».

А. Гыйләҗев иҗатын өйрәнергә алынган галимә буларак, мин аның киң карашлы, чиксез талантлы булуына, һәр әсәрен кабат-кабат кулга алып уйланырга, сызланырга мәҗбүр итә алган бөек язучы булуына гаҗәпләнәм. 1957 елда Б. Пастернак болай яза:

Смягчается времён суровость,
Теряют новизну слова.
Талант – единственная новость,
Которая всегда нова.

А. Гыйләҗев – талантлы әдип кенә түгел, намуслы гомер кичергән милләт хадиме дә! Аның 1989 елда язылган сүзләре бүген васыять кебек яңгыйрыйлар:

«Һәр милләтнең халыкны берләштерә торган, аңа бәхет, сәгадәт китерә торган уртак җаны туа. Яши. Әлегә без – дөньяда иң тарау һәм, кызганычка каршы, иң таркау халыкларның берсе. Кемнәрдер кай тарафларда яшәргә тели икән – яши бирсен. Кемдер туган төбәгенә, тарих билгеләгән газиз ватанына кайтып, аны яңартырга тели икән – кайтсын! Ләкин һәрчак, «давылларда, җилләрдә», якты көннәрдә дә, безнең рухны туплап торучы Җан булырга тиеш. Бар ул Җан. Ул – безнең гүзәл, сыгылмалы телебез. Ул – безнең шанлы-шәүкәтле башкалабыз Шәһри Казан. Ул – безнең Тукай, Насыйри бабайлар, Фатих Әмирхан пәйгамбәрләр мәңгелеккә күчкән зиратыбыз. Ул – безнең мәчет манараларыннан безгә баккан яшь аебыз. Һәм шушы көнгәчә иманыбызны сындырмыйча буыннан-буынга саклап килгән меңнәрчә милли каһарманнарыбыз. Миркасыйм хәзрәтләре исәпләп чыгаруы буенча, Идел–Чулман–Нократ төбәгендә инде йөз илле миллион татар булып киткән. Алар кылган яхшылыклар вә изгелекләр, алар кылган хата-ялгышлар – һәммәсе дә безнеке. Карлыгачлар бер Җан булып укмаша алганда, без дә, шушы җирдә гаделлекне яшәтер өчен, бер һәм бердәм булырга тиеш!..

Татарны ярату бүтән милләтләргә дошманлык белдерү түгел ич ул!»

Кадерле укучы! Китапны кулга алуга, татарның әдәби мирасына зур өлеш керткән язучыны искә ал, хөрмәтлә һәм укып ләззәтлән!

*Миләүшә Хәбетдинова,*
филология фәннәре кандидаты
доцент, КФУның туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендә
стратегик тикшеренүләр фәнни белем бирү үзәгенең
өлкән фәнни хезмәткәре

# Аяз Гыйләҗевнең автобиографик язмалары

## Үзем турында үзем[1]

Мин үзем күргән, тормышлары, яшәешләре, кылган гамәлләре белән мине баеткан бик күп кешеләр алдында зур бурычлы әле. Мин унҗиде яшемә хәтле авылда яшәдем. Сугыш еллары һәм аннан соңгы еллар иде бу. Шул елларның истәлеге минем өчен аерата газиз һәм кадерле. «Берәү»[2], «Дүртәү»[3] повестьларында мин бу истәлекләрнең бер өлешен язарга тырышып та карадым. 1972 елда «Язгы кәрваннар» һәм «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» исемле кечкенәрәк күләмдә ике повесть яздым. Бу – минем үземнең авылдашларыма, якты шәхесләргә, Югары Баграж кешеләренә, Зәй буйларына бурычымны кайтаруым гына. Әсәрләргә геройлар тормыштагы үз исемнәре белән кермәсәләр дә, географик һәм биографик дөреслеккә ябышып ятмасам да, бу әсәрләр – минем янәшәмдә яшәгән гүзәл авылдашларым турында. Яшәгән саен, миңа алар хезмәтенең гадилеге һәм бөеклеге, алар яшәешенең матурлыгы һәм авырлыгы ныграк күренә сыман. Моңарчы язылган әсәрләремдә берникадәр тарлык барын үзем дә сизеп йөри идем, тәнкыйтьчеләрнең дә сүзе урынлы булды, әмма мин үзем белгән, үзем яраткан кешеләр алдында бурычлы булып калмаска тырышырмын.

Хәзер дә тормыш белән бәйләнышны ычкындырмаска тырышам. Ел саен диярлек үз авылыбызга кайтам, башка төбәкләргә чыгам, йөрим. Тормыш көнләп түгел, сәгатьләп

[1] Әлеге мәкалә 1967 елда чыккан «Тәрәзәләр» җыентыгына кереш сүз буларак языла, 1972 елда әдип мәкаләне бераз үзгәртә.

[2] Язучы бу әсәрен 1959 елда яза башлый, төрле сәбәпләр аркасында повесть 1966 елда гына басылып чыга.

[3] А. Гыйләҗевнең 1956–1957 елларда язган хикәясе.

үзгәрә. Тормыш агышыннан ычкынып төшеп калмаска кирәк. Барыбыз да шуңа омтылабыз. Тормыштан артта калмас өчен, аның хәрәкәтен генә түгел, үзгәрмәс кыйбласын да яхшы белергә кирәк. Туган иленә, халкына бирелгәнлек, туган теленә сүнмәс мәхәббәт — менә ул язучының үзгәрмәс кыйблалары! Тормыш шартлары, яшәү күренешләре көнләп-сәгатьләп үзгәреп торса да, бу бөек төшенчәләр — мәңгелек, һәм шушы мәңгелеккә тугры кешеләр генә үзгәрешләрне халык белән бергә сиземли алалар.

*1972*

## Балачак сукмаклары[1]

*(Автобиографик эссе)*

### 1

Әйе, бүген дә, алтмыш яшьне үтеп, ашыга-ашыга җитмешкә тәгәрәгәндә дә, мин җәяүле сукмакларга тыныч кына карый алмыйм. Олы юлларны аркылы-торкылы кисеп үткән гап-гади сукмаклар миндә татлы хисләр, җылы тойгылар уяталар. Кая гына барсам да, поезддамы, автобустамы — мин ихтыярсыз тәрәзәгә ябырылам: уңга-сулга, урман ешлыкларына, әрәмәләрнең сихри кочагына кереп киткән сукмакларга карап, хыял дөньясына чумам. Шушы, меңнәрчә адымнар белән такырланган, инеш-күл буйларын чәлмәп ураган, карурманнарның серле дөньясы аша үткәрүче, зарыктыручы, кавыштыручы уравыч тар юллардан дөньяның иң бәхетле адәмнәре йөридер, дип фараз кылам. Әнә алар, кабаланмыйча, бер-берсен очлы терсәкләре белән борчымыйча, дөньяның кабатланмас гүзәллеген туя карап, зәп-зәңгәр күк, ямь-яшел җир белән аңлаша-аңлаша, болын, урман чәчәкләренең куе исенә кинәнеп, бәхет диңгезендә йөзәләрдер төсле.

[1] Әсәр беренче тапкыр 1998 елда «Зәй офыклары» (12—17 гыйнвар саннарында) һәм «Мәдәни җомга» (№ 4) газеталарында басыла. Алга таба «Идел» (2001, № 5), «Мирас» (2004, № 9) журналларында дөнья күрә. «Хәтер» нәшриятында — «Сайланма әсәрләр» (2004), Татарстан китап нәшриятында чыккан «Аяз Гыйләҗев. Истәлекләр» (2006), «Сайланма әсәрләр» (2016) китапларына кертелә.

Бәләкәй чакта сукмаклар синеке! Ялантәпи тып-тып басып дөнья белән танышу әнә шул җәяүле сукмаклардан башлана. Кая карасаң да – сиңа ят ярлар, моңарчы син күрмәгән, күрә дә алмаган сер дөньясы.

Балачак хатирәләре – әкрен аккан, өзек-өзек ак болыт кебек истәлекләр – бер-беренә ялганмыйлар, әллә кайда, шул серле сукмакларда уралып, еракта, томанлы офыклар артында тынып калган вакыйгалар һичкайчан да бер-берсенә чылбырдай тоташа алмыйлар. Алсу шәүлә дә кебек алар, таңда яңгыраган сак җыр да сымак, кайчан булып үткәннәрен өзеп әйтеп тә булмый. Балачак хәсрәтне белми, ә вакыт белән янәшә яшәү хәсрәт килгән көннән генә башлана...

Тәңремә рәхмәтлемен: ул мине туганда ук шигъри күңелле иткән. Шулай уйлыйм, хәтергә нык сеңеп калган вакыйгалар шуны сөйли.

Җәйләрнең берсендә әнием ындыр түрендәге кыяр түтәлләре арасына барып кергән. Мин, терсәкләремә таянып, артымны туңкайтып, борын очым белән җир сөреп, чәнти бармак кадәрле үскән кыяр малаен кимереп ятам икән... Әни, соң дәрәҗәдә гаҗәпләнеп: «Улым, нигә кыярны ятып ашыйсың?» – дип сораган. Мин, аллы-күкле янып: «Үзең өзмәскә куштың ич!» – дип җавап биргәнмен, имеш. Җавабымны үзем хәтерләмим, әни сөйләвеннән исемдә калды, ул ышанып сөйләгәч, шул вакыйга бала чагымның иң кадерле хатирәсе булып күңелемдә саклана.

Минем әтием – тумышы белән Сарман кешесе, үз-үземне белә башлаганда без Югары Бграж дигән гүзәл керәшен авылында, нәкъ чиркәү каршысындагы пуҗымда[1], Әндриян дәдәйләр өендә яши идек. Таза ихата, йорт-җир байларча биек итеп салынган, җәен салкынча, кышын зәмһәрир суыкларда да җылы була торган калын стеналы таш амбарны мин аерата ярата идем. Әндриян дәдәй – балта остасы, аны Федоттагы ятим балалар йортына эшкә чакырып алганнар да, ул гаиләсе белән шунда яшәп ятканда, без алар өендә тордык. Минем татлы, кадерле балачак истәлекләрем Җир шарының шушы нәни ноктасы белән бәйләнгән. Каршыда,

[1] Пуҗым (*диал.*) – йорт һәм бәрәңге бакчасы урыны; ихата. (Астөшермәдәге сүзләр төзүче тарафыннан куелды.)

бакча эчендә, чиркәү, унда – мәктәп биналары, мәктәп каршысындагы киң генә мәйдан миңа, шактый елгыр малайга, яшәү серләрен ачып биргән кадерле урыннар иде.

Әндриян дәдәйләр бакчасы кояшка таба авыш, ул, сөзәкләнеп, ындыр артыннан үткән Метри елгасына төшә. Язын әз-мәз сулы, ташу кузгалганда ике-өч көн дулап алып, җәйге челләдә кибеп корый торган Метри ярында әти яшелчә бакчасы ясады. Яфракларыннан татлы ис таратып утыручы юаш карлыган куаклары да шунда тезелде. Кыяр, кишер, чөгендер, помидор янәшәсендә Югары Баграж өчен ятрак булган кавын-карбызлар тәгәрәп үсте. Кунак-мазар килгәндә, әти аларны, чәй эчкәнче үк, бакчасына алып төшә иде. Әти урта мәктәптә химия, биология укыта – иртә-кич бакчада казынырга нык ярата иде.

Соңгы сигез гасыр эчендә дөньяда табигатьнең иң мәрхәмәтле еллары утызынчы белән кырыгынчы еллар арасына туры килгән. Җир сирәк тетрәгән, зилзиләләр сирәгәйгән, янар таулар яман утларын сак түкергәннәр, җәйләр җылы, мәрхәмәтле, шәфкатьле булган. Утызынчы-кырыгынчы – минем бәхетле бала чагымның еллары! Мин хәзерге әле коры, әле яңгырга тоташ манчылган җәйләрне ул бәрәкәтле еллар белән чагыштырып карыйм, һәм хәзерге заман балаларын уйлап күңелем сызлый... Җир мәрхәмәтле, сөйкемле еллары белән дә безне иркәләгән икән!

Агач чиркәү! Аның безнең тәрәзәләргә караган диварына, өскә үк, «1840» саны сугылган сары калай кадакланган. Без бәләкәй чакта Баграж чиркәве үзенең йөз еллыгын үткәргән икән. Мин чиркәүнең биек-биек, янындагы озын чыршылардан да биегрәк күтәрелгән хачларын, эчендәге алтын-көмешле бизәкләрен, диварларына эленгән тәреләрен, чигүле тәре алъяпкычларын яхшы хәтерлим. Утызынчы елларда авыл коммунистлары – Озын Микәйлә, тагын кемнәрдер – чиркәү хачларын кисеп, түбә калайларын изә-изә, дөбердәтеп җиргә төшерделәр.

Чиркәүгә һәм Әндриян дәдәйләр өенә чапырышта, сул ягыбызда, мәшһүр каравыл өе. Шунда ук янгын сарае, ат абзарлары, күгәргән кул насослары, коргаксыган мичкәләре, лапас өрлекләрен терәгән шома сөян баганаларга ыргак,

багур, корымлы пумалалар асылган, дәү-дәү имән чөйләргә бөятләре ашалган камытлар, буяулары купкан дугалар, сүсәргән аркалык-түшлекләр, таҗ баулары эленгән. Без – Урта һәм Аскы урам малайлары – бәхетле! Әниләрнең «замат[1] арасында кайтасы бул, ыштубыты ишетсен колагың!» диюләренә карамастан, әбәдтән соң гел шунда уралабыз. Мич арасыннан, аулактан урын алып калырга кирәк. Менә каравыл өенә карт-коры җыела башлый, кичкырын, ипләп кенә, ирләр дә шунда тартыла. Алар вәкарь белән, ашыкмыйча күрешәләр, озын итәкле чикмәннәрен, иске пинжәкләрен чишеп җибәрәләр, челемнәрен кагып, тәмәке тутыралар. Һәм китә сүз! Ишек шар ачык булса да, өй эче тиздән төтен белән тула, ләкин без кымшанмыйбыз, киресенчә, мич арасыннан башта елтыр танаулар күренә башлый, аннары баш күренә, муеннар сузыла. Ашау, өй, әнинең кисәтүләре истән чыга, кумасыннар гына!.. Кызык сүзләр, мәзәкләр, дәмәкләр[2] шунда сөйләнә... Инде Багражның атаклы сунарчылары Аксак Ибан белән Сәвәләй Питеры да килеп керсә... бетте! Без төнгәчә аларның маҗараларын тыңларга әзер. Түтәл тәмәкесеннән төрелгән «кәҗә сыйраклары» чытыр-чытыр яна, йөз ел юылмаган тәрәзәләргә эңгер иңә, идән өстенә яңа керүчеләрнең алапай чабаталарыннан туфрак коелып, яңа катламнар ясала, ә безгә рәхәт. Керәшеннәр – үтә сабыр, бер-берсенә итагатьле халык, ничә еллар яшәп, багражлыларның үзара сугышканын, талашканын күргәнем, ишеткәнем булмады. Багражда олылар – олы, кечеләр – кече...

Кем ничек кушкандыр, берзаман каравыл өе адәмнәре янына мин үз бакчабыздан бер кесә кыяр тутырып килдем. Бусын үзем дә ап-ачык хәтерлим!.. Дәү-дәү, көрәк сакаллы керәшен дәдәйләр мине кызык өчен генә кыяр урларга җибәргәннәрдер дип уйлыйм, борчак кузагы дәүмәлеге кыярларны күреп: «Ник мондый вакларын өздең?» – дип сораганга, «Олыракларын күтәреп булмый шул аның!» – дип җавап бирдем. Үзем оялып, пешеп-янып идәнгә текәлдем һәм нәп-нәни кыярларны идән ярыгыннан берәм-берәм базга шудыра башладым.

[1] Замат (*диал.*) – тиз, бик тиз, күз ачып йомганчы.

[2] Дәмәк (*гар.*) – кызык, мәзәк.

Оялуымны, чәнти-чәнти кыярларымны, ирләрнең көлеп җибәрүләрен бүгенгедәй хәтерлим.

Авыл малаеның балачак хатирәләре кыяр-шалканнан башлана икән, моңа һич гаҗәпләнергә кирәкми. Авыл баласы үзенең эшчәнлеген, хезмәтен әнә шул бакча түтәлләреннән башлаган.

Әтиемнең Сарман тумасы икәнен әйткән идем инде, әнием Мөгаттәрә дә шул төбәк кызы, Сарманга терәлеп үк торган Югары Әхмәт авылында туып үскән. Әти Минзәләдә педучилищеда укый башлаган, әнием шунда ук кызлар мәктәбендә белем алган. Минзәләдә танышканнар алар, шунда кавышканнар. Әтине эшкә Чукмарлы авылына җибәрәләр, әни бер-бер артлы өч малай табып, өйдә утыра. Әтине, яшь мөгаллим дип, район читендәге Югары Баграж авылына укытырга җибәрәләр, авыл Зәй районы карамагына күчкәч тә, безнең гаилә Багражда калган. Минем балачагым, яшьлегем әнә шул авылда, юмарт күңелле, кунакчыл, гади, үтә кешелекле, риясыз-хәйләсез керәшеннәр арасында үтте. Олысы-кечесе безне хөрмәт итә иде. Көрәк сакаллы, абруйлы авыл агайлары, әниемне яратып, гади укытучы хатынын зурлап, «апа» дип эндәшәләр, әллә каян, ерактан, бөгелә-сыгыла сәламләп киләләр иде. Әнием оста җөйче иде, Баграж сылуларына чуклы-чачаклы түшле, бәбәйтәкле күлмәкләр тегеп кигертә башлагач, аның абруе тагын да үсте. Ата-ананың абруе авыл арасында малайларны да үзсендереп җибәрә. Хәтеремдә: авыл уртасындагы мөгәҗи[1] амбарына айбагар[2] кайтарып тутырдылар. Кояшлы көннәрнең берсендә айбагарны амбар алдындагы чыбылдыкларга чыгарып тараттылар. Керәшен авылында айбагар йорт буенча тулып ята, шулай да малайларның күзе амбар тирәсендә... Айбагарның үзе түгел, шуны чәлдерергә маташу дәмәк!.. Амбар артыннан шыпан-шыпан чыгып, кесәләргә айбагар тутыра башлаган гына идек, тап-таза Югары оч егете Миндәй Ибаны якадан эләктермәсенме?! Яра инде дип торганда, Ибан минем кем

---

[1] Мөгәҗи (*гар.*) – авыл халкы тарафыннан гомуми фондка салынган игенне саклау урыны, келәт.

[2] Айбагыр (*диал.*) – көнбагыш.

малае булуымны белгәч йомшады, кесәмә айбагарны шәпләп үзе тутырды...

Озын кышларны кая да чыгып йөрмибез, Багражда үткәрәбез, язгы-җәйге бәйрәмнәргә – җыенга, Сабантуйга – без Сарман, Әхмәт якларына кайта торган идек. Хуш исле йомшак печән түшәлгән тарантаска гаилә белән төяләп, мәктәп атын җай белән генә атлатып, егерме чакрымны – Сарман – Баграж арасын үтүләр татлы төш булып истә калды... Завод үрен менгәч, юл урман эченнән үтә, ә анда каен җиләге, кып-кызыл келәм булып, кызыктырып, җанландырып, безне көтеп ала торган иде. Табигатьне олылау, аны изге санап баш ору безнең заман кешеләрендә үтә дә көчле иде! Без малайлар да җиләкне алан читеннән, таптамыйча, берәмтекләп җыя идек. Башта «кызыл сандык»ка – авызга шудырасың, аннан берәр савытка күчтәнәчкә җыя башлыйсың. Җир-су чиста, болытлардан көмештәй яңгыр ява, җир хәзинәсе – җиләк-җимешләр – әле саулык кына китерә!

Гаҗәп, бәләкәй чакта мин Сарман урамнарына калай җәелгән, ә Нөркәй дигән авыл кешеләре очлы түбәле брезент юрталарда яшиләр дип белә идем. Малай кеше аякка киеп торамыни? Күп кешеле Сарман урамнары нык тапталып, җәйге челләләрдә көйдерерлек кызгандыр шул! Мин шулай дип хәзер генә, шушы хатирәләрне язган чакта юрадым. Ә нөркәйлеләрне ник брезент юрталарга күчергәнмендер, аңламыйм, бәлки, әтиләр белән Нөркәй авылын узып та киткәнмендер?

Исемдә, тәбәнәк кенә, йомры гына ике малай: әтинең бертуган абзыйсы Мәхүбрахман абыйның улы – яшьтәшем Максут белән алар капкасыннан ишегалдына кереп киләбез. Куллар артта, йөзләр җитди, авызлар йомык. Әниләр безгә карыйлар да башта... кычкырып көләләр! Ә аннан соң... куллары кычытканга үреләә. Тикшереп карасак, икебезнең дә түшләр сап-сары икән... Ни хикмәттер, дүрт яшьләрдә чакта икебез дә чи күкәй эчәргә ярата торган идек. Гелгел ояга менәргә әниләр рөхсәт итмәгәндер шул, ара-тирә күршеләрнең тавык ояларына да походка чыкканбыздыр... Шуны уйладым исә, мәшһүр шагыйребез Һади Такташның «Мокамай йомырка урлаган» дигән тәүге шигыренең юлла-

ры искә төшә. Һәр Мокамайның Әйшә тәтәе була, бәләкәй чакта татыган «кычыткан себеркеләр» ул чакта урлашмаска өйрәткән әче сабак була торган иде.

## 2

Дүрт яшемдә идемме, әллә якты кояш астында бишенче җәемне үткәрә идемме, безнең авылда балалар бакчасы ачтылар. Аны «Площадка» дип атадылар. Урак өсте иде шикелле. Минем әни белән Югары очның Феона апа Васюкованы тәрбияче иттеләр. Үзләре ашчы, караучы, җыештыручы, кер юучы да иделәр. Шуның өстенә әни малай-кызларга пардан җәйге киемнәр дә текте. Ул чактагы рәхәтлекләр! Су коенырга йөрибез, авылга авып торган тау тезмәләре битләреннән җиләк җыябыз, олы малайларның ат коендырганын бергәләп карыйбыз. Мин атларга якын ук килергә куркам, читтән генә, сагаеп, яр буе таллары арасыннан карап торам. Ник дигәндә, берзаман әти белән мәктәпнең Аманат исемле атына утырып кайттык та, әти Аманатны тугарып җибәрде, мин сарай ишеген ачарга йөгердем. Аны-моны искәрмичә барам, башын чайкый-чайкый артымнан фырлап килгән Аманат кинәт җилкәмнән умырып алды да мине алагаемга чайкап җибәрде. Акырып еларга тотындым, аркам канады. Аманат тешләренең эзе шактый вакыткача җөйләнеп торды. «Аткамы, бүтән хайваннаргамы телең белән тәмләп эндәшмичә, берчакта да алдына төшмә!» — дип өйрәтте әти. Мин гомерем буе аның киңәшен тоттым, тик, ни хәл итәсең, йорт тирәсендәге мал-туарлар, кош-корт әтинең киңәшен белмәгәндер шул: үз гомеремдә мине өч тапкыр каз талады, дүрт-биш мәртәбә кәҗә тәкәсе сөзде, колхозның иң дәү ата дуңгызы төртеп екты, бер тапкыр Имәнле урамында ана күркә кычкыртып талады.

«Площадка»ның кайда, кем өендә урнашуы ныклап исемдә калмаган, мәгәр без Метри елгасы тирәсенә Каравыл почмагыннан Макар дәдәйләр, Ипис түтиләр ызанынннан төшеп йөри идек. Елга аръягында искиткеч матур, аллы-гөлле чәчәкләр каплаган бәләкәй генә болын бар иде. Иртә яздан кара көзгәчә чәчкәләр бер-бер артлы ачылалар да, җәйнең

һәр күләмендә болынның үзенә хас чәчкә исе була торган иде. Беркем кисәтмәсә дә, болынга аяк баскан кеше кинәт үзгәрә, чәчкәләрне өзмәскә, үләннәрне таптамаска тырыша. Кай яктан җилләр иссә дә, алар тыгыз һавалы бу үзәнгә төшеп җитә алмыйлар, көн туса, без шул оҗмахта күбәләк куабыз, гөрле-качышлы уйныйбыз, әз-мәз таптап китсәк тә, без болыннан чыгуга, үләннәр рәхәтләнеп турая торганнар иде. Еш кына болынга, эштән бушаганда, әти дә төшә, безне түгәрәкләп тирә-ягына утырта, гонҗә-үләннәрнең исемен атап, берәм-берәм күрсәтә башлый. «Безнең якларда ашарга яраган йөзләп үлән бар»,– дия иде. Ниләр генә җыеп ашамый идек без Баграж болын-урманнарыннан! Җиләк-җимешне, гөмбәләрне әйтеп тә тормыйм, язга чыгып кар китүгә, кояшка караган ермак ярларына сап-сары булып бакыр тәңкәләр сибелә. Кимәшә башын бүксәң кап булганчы аша, зыяны юк. Кимәшә башына ялганып, урманда, көздән калган коры яфракларны аралап, күке башы калкына. Аланнарда кузгалак үсә, кыр какысы, урман какысы котырып уңа... Төрле якларда әнис, җир бәрәңгесе, карабаш, балтырган җыярга йөрибез. Олы су башында – сарана!.. Кәҗә башы урамыннан ындыр артларына төшсәң, ни генә юк анда: песи борчагы, карга борыны, шепкән... Тыкрыкларда кычыткан кыяры үсә. Карга борынының тамарга торган җиләген ашыйбыз, шепкән уабыз. Шома көпшә, сасы көпшә, чуар көпшә. Җаның ни тели!

Эссе җәй! Яндыра! Быел коры җәй, ләкин без яраткан болынның дымы бетми, без, икешәрләп тотаклашып, Метри елгасына таба төшеп барабыз. Алдан юл күрсәтеп әни бара, ыбыр-чыбыр бәрәңге арасында адашып калмасын дип, арттан үткер күзле Феона апа атлый. Нәкъ каршыбызда, елга үзәненең аръягында, ундарак – унбиш-егерме йортлы Имәнле урамы. Урам очында – Чулак Кунуннар йорты. Үкличә киртәсе алар ихатасына тоташкан. Үзем күрдем, әнигә ияреп көтү каршыларга барганым бар. Кунуннарның Ладимыр исемле куш түбәле базык уллары да «Площадка»га йөри, без хәзер шуның белән җитәкләштек. Булса да булыр икән шук бала! Ладимыр берәүгә дә тынгы бирми, кызларның толымыннан тарта, толымы юкларның бармагын тешли, малай-

ларны чалып ега, су коенганда, кызларның күлмәгенә таш бәйләп буага ыргыта. Үзе көчле, үзе алагаем хәйләкәр. Бу «терекөмеш» мәктәпкә кергәч тә укытучыларның җыгын чыгарды. Дәрестә утыра алмый иде, мәктәп базына кереп чума, теленә нинди җыр килсә, шуны акырып ята... Имәнле урамы хәзер юк, бетте, таралды. Ладимыр яшьтәшем дә күптән инде гүр иясе булды. Үскәч, акыллы, үтә сабыр, ипле кеше иде, шофёр булып эшләде, көтү көтте... Сирәк кенә сагынышып очраша торган идек. Урының җәннәттә булсын, яшьтәш!

Төшеп барабыз, әни, күз алдында булсынга, аны алгы парга куйган, шунда да ул мине чалып егарга маташа. Тезләре кутырлап беткән, иягендә җөй, иреннәре мыймылдый, колагы селкенә – һич тик бара алмый! Күзем Имәнле урамы өстенә эленгән печән кибәне дәүмәлеге болытка төште. Болытны чамалап, әни дә туктап калды. Зәп-зәңгәр иде күк, каян яралды әле бу аклы-каралы иләмсез болыт?! Капылт кына әллә ни булды: зәңгәрсу кызыл сызык болыттан аерылды да түбәнгә, җиргә, Имәнле урамы өстенә атылды. Күк яман чартлап урталай ярылды, гайрәтле күк күкрәвеннән без җиргә егылдык. Әни, борылып: «Балалар!» – дип кенә әйтә алды. Аяк өстендә бер Ладимыр гына басып калган икән. Имәнле өйләре өстеннән ургылып чыккан төтенне әүвәл ул абайлады, яшелле-мөшелле тавыш белән: «Пужар! Пужар!» – дип акырырга тотынды. Озак та үтмәде, тирә-якка искәртеп, чиркәү чаңын кага башладылар. Әни белән Феона апа, тилгәннән качып кайсы кая таралган чебиләрне җыйган төсле, безне көч-хәл белән җыйдылар. Бер кыз куркуыннан Метри елгасының төбенә үк тәгәрәп төшкән икән. Утыра шунда посып, үги ана яфраклары арасында! Без бәрәңге сабакларын таптый-таптый каравыл өенә менеп җиткәндә, анда мәхшәр башланган иде инде. Тик ятып үшәнләнгән каравыл атлары чаң тавышыннан куркып тәртә арасына керми интектерәләр, пожарниклар да каушаган, алар ат сыртына каеш камчы белән тамызалар. Атлар аның саен киреләнә, йөгәннәрен тартып хырылдыйлар. Күпердән әйләнергә ераксынган Урта урам адәмнәре, чиләк, көрәк, багорлар тотып, без менгән сукмактан гына Метри елгасын кичеп, янгын ягына элдерделәр. Башта аклы-каралы куе төтен бөркелгән

иде, соңра ялкын телләре сузылды, бераздан Имәнле урамы тоташ учакка әйләнде. Әллә-лә! Яна Имәнле урамы, дөрли, ә яман гадәтле алама болыт, «сау булыгыз!» дигән төсле, авыл күген бер әйләнде дә үтеп китте. Ут янына чабарга шүрләгән карт-коры каравыл өе янына җыйналды. Телләрдә бер сүз: «Вәт Ходаның хикмәте, ишеп яуса соң! Нигә утын гына ташлап калдырды бу болыт, шоннок[1]?!»

Унбер йорт нигезенә кадәр утырып янды.

Кага-кага, чиркәү чаңын урталай ярганнар...

«Эзейдән дә килделәр, тирә-яктагы унбиш авылдан атлар килде»,– дип сөйләде соңарган кичке чәй янында әни. Ул төнгә әни «Площадка»га ашыкты, ул төнне Имәнле урамы балаларын шунда кундырдылар. Әни шуларны карап, ашатып, «Площадка»ны саклап чыкты.

Мин бик озак йокыга китә алмадым, иләмсез болыттан аерылган дәһшәтле ут күз алдымнан китмәде. Йоклагандай булам да куркып, кычкырып уянам. Ичмасам, янымда әни дә юк!

Шул көннән мин болыттан, яшен утыннан, күк күкрәвеннән курка башладым. Офык читендә каралҗым болыт куера башладымы, өйнең берәр почмагына кереп качам. Тик яшен камчысының агы шулкадәр көчле – кермәгән тишеге, үтә алмаган почмагы юк. Чоланда дәү агач сандыгыбыз бар, артына кереп посам – яшен чартлый-чартлый мине эзләп таба. Толыпка уралып мич арасына кереп утырам – колагымны ярырдай күк күкри. Ахырда әмәлен уйлап таптым. Олылар йоклый торган караватбашына әни мендәр-ястыкларны өеп куя иде. Чак кына болыт кабарды исә, шул мамык тавын ишеп төшерәм дә ястык-мендәр астына кереп йомылам. Яңгыр килгәндә, ишек-тәрәзә тыгызлап ябыла, мич төннекләре томалана, өебез бәләкәй, бөркү, эссе. Ястык арасында мунча ләүкәсеннән мең яман, тын җитми, шабыр тиргә батам, манма су булам, ләкин курку барысын да җиңә.

«Курку – иң явыз көчләрнең берсе»,– дип аңлата әти, мине батыраерга чакыра. Бу курку хисеннән мин озак арындым, хәзер яшенне бар дип тә белмим, хәтәр давыллы сәгатьләрдә, каралҗым караңгы күк явызланып ут чыбыркысын болгаган-

[1] Шоннок (*диал.*) – гаҗәп, искитәрлек.

да, Идел уртасында балык тотып утырганым бар. Әллә нинди яшен сәнәкләре күз алдымда болытлардан аерылып биектә яман сызылып барды – каушамадым. Курку, хатирә булып кына калганда, әллә ни зыянлы түгел икән үзе!

## 3

«Улыбыз үсә!» – дип, әти белән әни куаналар. Күршекүлән, килгән-киткән кунаклар да мине алларына бастырып мактыйлар. «Үскән, егет булган ич улыгыз!» – дип, әниләрнең сөенечен арттыралар. Бала-чаганы мактаган саен, сыйның мулрак, тәмлерәк эләккәнен хәзер генә аңлыйм – үзем дә өч бала атасы...

Үсү шулдыр инде: хәзер үзем генә дә көтү каршыларга барам, үткен күзле, корыч томшыклы тилгәннәрдән бәбкәләрне дә энем Алмаз белән бергә саклыйбыз. Сыер абзарын тазартырга, ишегалдын себерергә, малларга печән салырга әти белән чыгабыз. Эш арасында әти янында уралу иң рәхәт чаклар булган...

Үсте, дисәләр дә, бәләкәй шул әле мин! Үземнән ике яшькә генә олы Азат еш кына мине тәпәләп ала. Менә ул үскән ичмасам! Шкафның иң өске киштәсенә үрелә дә прәннекне чәлдерә, мин сорасам, муен тамырыма кундыра. Азат үскән, ичмасам, ул мәктәпкә йөри, ул – укучы, аның белән чамалап сөйләшергә кирәк. Олы малай буларак ул әти белән утын кисәргә чыга, пычкының бер башын ул тарта. Мин әти ярган утынны ышыкка, лапас астына ташыйм, ә энекәшем Алмаз җиз таска түбәләмә итеп йомычка җыя. Баграж авылын өч яктан урманнар ураган булса да, безнең әти әрәм-шәрәм иткәнне өнәми.

Үскәнмендер дә шул: хәзер мин бик күпне беләм. Безнең бабай Сарманның иң ярлы «Ак ыштаннар мәхәлләсе»нең имамы булган. Әтинең Нурлыхода, Маһиәнвәр, Әсма атлы апалары бар, Сарманда элегрәк телгә алган Мәхүбрахман абый яшәп ята. Элеккеге «Мөхәммәдия» шәкерте, зур укымышлы, зыялы кеше, скрипкачы, һәрьяктан талант иясе. Бакчачы, җиләк-җимеш үстерү остасы. Агач утырту, күпер юллары төзәтү, табигатьнең кадерен белү безнең нәселдә-

ге һәр кешегә хас. Нурлыхода түтинең ире Ризван мулланы күргәнем юк, ахрысы, ә аларның бердәнбер уллары – Хәмзә исемле искиткеч чибәр, бөдрә чәчле, көр тавышлы егет – безгә еш-еш кунакка килеп йөри. Без дә аларга баргалыйбыз. Әсма апаның Лена, Илтөзәр, Раҗия исемле балалары да безгә килеп чыга, безнең яшьлек чорында туганнар еш аралаша иде, бер-береңә хөрмәт, хәл-әхвәл белешү көндәлек гадәткә кергән, канга сеңгән иде. Безнең йортка иң еш килеп йөргән кеше әтинең тол апасы Маһиәнвәр булгандыр. Без аны кыска гына «Әнвәр түти» дип атап йөрттек. Әнвәр түти, еш килү өстенә, бездә бик озак, икешәр-өчәр ай торып китә иде. Көзгә кереп бакча эшләре тәмамлангач, сугымнар суелгач, каз өмәләре үткәч килеп төшә дә язга кадәр кунак була. Үз гаиләсе булыр-булмас, кияүгә чыгып тиз үк аерылып кайткан бу апабыз әз генә йокычан, әз генә юбалгы[1], мунчага барса, дүрт-биш сәгатьсез чыкмый торган тәмлетамак карчык иде. Каратут йөзен, шактый күләмле борынын гына калдырып, башын яулык белән урап куя торган бу апа гомере буе кара-көрән, озын итәкле күлмәк яратты, яулыкның да агын бәйләми иде шикелле. Бу ятимә карчык, олылардан аерым хөрмәт күрмәсә дә, безгә килергә ярата иде. Дөрес, аның өс-башын карыйлар, тамагы сыйлы, урыны түрдә, мәгәр олы кунак-мазар килгәндә, аны табынга алмыйлар, бәлки, ул үзе шулай теләгәндер, әмма кеше барында, кече якка чыгып Әнвәр түти ашап утырганда, мин аны үтә нык кызгана идем. Шунысы да бар: күпме яшәсә дә, ул мәңгелек кунак, өй эшләренә катышмый, сирәк-мирәк идән себергәли иде, мендәр-юрганны кагарга көнгә алып чыга. Яше олы булса да, намаз укымый, мин аның дога укып, амин тотканын да хәтерләмим. Ул шушы дөньяда тарсынып, нәрсәдәндер кыенсынып яшәгәндер, ахрысы. Хак: зарланганын ишеткәнем дә булмады, җылаганын күрмәдем, йомылып, үз уйларына батып яшәүче бу сәер апага мин аерата нык тартыла идем.

Үзара дус идек без.

Менә олылар кайсы кая тарала. Киндер букчасын асып, Азат мәктәпкә китә, Алмаз – уенда. Без түти белән өйдә икәү калабыз. Кайчагында гына Алмаз да өйдә була. Урамга чы-

[1] Юбалгы (*диал.*) – ялкау, җыйнаксыз һәм шапшак (кеше).

гар иден, карлы яңгыр коя, тәрәзәләр парланып томаланган, җил ян бакчадагы шомырт агачларының соңгы яфракларын талап улый. Шундый аулак чакларда Әнвәр түти капылт үзгәрә, аның хәсрәтле җыерчыклар белән каймаланган каппкара күз тирәләре җанлана, нурлана, ул яулыгын маңгаена күтәребрәк куя, каратут маңгаена чал сибелгән кара чәчләре сибелеп чыга. Аның җанлануын, күңелле үзгәрүен күреп мин куанам, түтине ныграк сөендерәсем килә, өстәлне, урындыкларны күчереп, өйне киңәйтәм, идәннән – сәкегә, сәкедән идәнгә сикереп, мәзәк ясарга тотынам. Авыз-борынымны мыймылдатам, телемне чыгарам, күзгене үчеклим, ишек катында мыштым гына утырган дәү галошларны киеп, лыпыр-лыпыр биегәндәй итәм. Берзаман галошлар, очып, ике якка барып төшәләр... Әнвәр түти, тагын да җанланып, минем маймыллануымны күзәтеп тора, ачуланмый, сүкми, көлә, тәне җиңеләеп китә. Аның да иңбашлары бер күтәрелә, бер төшә, йөзенә кызыллык чыга: ул, учын учка бәреп, такмак әйтергә тотына. Аның такмагы кыска, ике-өч сүздән генә тора, алай да минем йон оек кигән аякларым үзеннән-үзе сикергәли башлый, мин, идән уртасына чыгып, тыпыр-тыпыр биеп китәм. Түти җай гына, бер көйгә генә: «Сездә кем бар киндер суга, сездә кем бар киндер суга?» – дип, бертуктаусыз кабатлый. Аның сүзгә зарыккан иреннәреннән тавыш һаман көчлерәк чыга, ни озак такмакласа да, мин арымыйм, аның шушы гади такмагы мине котырта, дәртләндерә, шашындыра. Мин тәмам онытылганмын, түтинең колагы тышта икән, менә ул тынып кала, яулыгын төшереп бәйли, маңгаен яшерә һәм тынын тигезләргә мич арасына кереп китә. Андагы үзгәрешне күреп, мин телсез калам. Түтинең: «Кайттылар!» – дип пышылдавы гына мине игә китерә.

Әнвәр түти белән без корган театрны Алмаздан бүтән кеше күрмәгәндер дә, ул да, мин дә серне чыгармадык. Әллә күреп тә дәшмәделәрме?

Авыл өе бик бәләкәй булса да, элек аңа әллә ниләр сыя иде! Сыер бозауласа, бозавын күтәреп өйгә кертәләр, кышкы суыктан саклыйлар. Без малай чакта суыклар чыннан да суык була торган иде. Көздән, ноябрь башларында төшкән кар, язга кадәр шылт та итмичә, эремичә ята иде. Бозау ар-

тыннан сыер да өйгә килеп керә. Бозавын ялый, иркәли, куе угыз сөте белән аңа үсәргә көч бирә... Угыз коймагын без барыбыз да бик яратабыз. Коймак пешкән көн – елына бер килә торган бәйрәм. Ул көннең тагын бер бөек шатлыгы бар: мин, зур колхоз табагына[1] тотырып, күршеләргә угыз коймагы ташыйм! Күршебез Ипис түти, коймак керткәч, миңа бер уч чикләвек, бер уч айбагар бирә, бозау турында озаклап, бөртекләп сораша. «Маңгаенда кашкасы бармы? Бәкәле ак түгелме? Ни төсле?..» Үзең керткән күчтәнәч коймак белән чөгендер чәе эчә-эчә бозау турында сөйләү нинди рәхәт!.. Балачак рәхәтләре алар үзгә, аерата кадерле, аерата газиз...

Сыер өйгә кергәндә, мин, аның очлы мөгезләреннән куркып, мич арасына кереп качам. Әнвәр түти мине арттан кочаклый, мин, аның җылы тәненә тиеп, дөньямны онытып тынычланам...

Аулак калган мизгелләрдә без кәмит күрсәтеп кенә яшәмибез, кайчагында Әнвәр түти боз каткан тәрәзә алдына килеп баса, ике кулы белән ике тәрәзәнең ике яңагына ябыша һәм тоныкк кына бер көйгә җырлагандай итә. Тавышы юк аның, тавык кырлавыннан аерылмый, ләкин сабый булганмын, тутамның – ятим-ялпының, бичара толның – бертуктаусыз мөнәҗәт укуын белә алмаганмын. Сүзләрен аңлап бетермәсәм дә, мин аның тәрәзә аша йотылып үз балачагына кайтканын, кемнедер сагынып, юксынып мөнәҗәтләр укуын үтә дә ярата идем. Андый чакларда түти түгел, мин сагаям, капка әз генә шыгырдады исә, «Кайттылар!» – дип пышылдыйм... Уртак серебезнең дөньяга фаш булуын теләмим...

Менә безнең «гаилә» ишәя: исәя башлаган, мөгезләре төртеп чыккан наян бозау янына берәм-берәм сарык бәрәннәре кереп кушыла. Бәрәннәр тиз үсә: атна дигәндә өйгә алар хуҗа була! Җитмәгән җирләре, аудармаган нәрсәләре калмый. Иләк, чиләк, ипи табаклары һәр көн күчеп, күченеп йөриләр. Өй тарая, бозауны, муенчаклап, аралыктагы тимер боҗрага бәйләп куялар. Бәйләп куймый кара, бәрәннәргә ияреп алдын-артын сикертеп чаба башласа! Беркөн ычкынган да ашлы сулар җыя торган лаканны аударган. Әй эләкте Әнвәр түти белән миңа!

[1] Колхоз табагы – уртачадан зуррак бадьян.

Бозау, бәрәннәр белән аулак өйдә калырга ярата Әнвәр түти. Ул аларны кочаклый, муеннарын кашый, чәйнәп ипи йомшагы каптыра, дымлы борыннарын үбә. Бәрәннәр аның саен наянланалар, кушаяклап сикерәләр, ишекле-түрле ду килеп чабалар. Муенчагын өзәрдәй булып аралыкта бозау сикерә, Әнвәр түти идән уртасына чыгып баса да, учларын шапы-шопы китереп, үзенең мәңгелек такмагын кабатлый: «Сездә кем бар киндер суга, сездә кем бар киндер суга!» Бәрәннәрнең нәни тояклары дер селкеткәннән бүрәнә арасыннан мүк коела, кыстырган җиреннән уклау атылып чыгып идәндә бии, кисәү агачлары, җәмки[1], самавыр торбалары, ухватлар дер-дер селкенәләр. Андый чакта тик торып буламыни? Мин дә өйдәге хәрәкәткә кушылып китәм һәм Әнвәр түтигә ялгап такмак әйтә башлыйм... Юк, аның сүзләрен кабатламыйм, минем үземнеке, үзем чыгарган такмак бар...

Чыгарган беренче такмагым – шигъри юлларым хәтердә калмаган, соңгы бер юлы гына исемдә... Әлбәттә, ул шушы бөдрә йонлы, тере күзле шук бәрәннәргә багышланган иде... «Идәндә шомырт коя» иде аның соңгы юлы... Баштагы юллары «Яфрак ярата бәрәннәр... тамаклары тиз туя... Тамак туйгач, сикергәләп, идәнгә шомырт коя» булды шикелле... Ни гаҗәп, Әнвәр түти минем такмакка игътибар итте, «киндер сугучыны» онытып, миңа ияреп, мин чыгарган такмакка күчте, без икәүләп идәндә сикергәләдек, керәшенчә әйтсәк, уармак[2] килдек, дәмәк ясадык.

Иртәгесен без тагын аулакта калдык, бүтәннәрнең аяк эзе тынгач, бозау, өч бәрән, Әнвәр түти һәм мин пәри туен башладык... Һәм Әнвәр түти кичә мин чыгарган такмакны кабатлый башлады... Бу хәл миңа көч бирде, дәрт өстәде... Шул көнне мин яңа такмак чыгардым. Анысы аралыкта моңаеп торган бозауга багышланган иде сыман...

---

[1] Җәмки (*диал.*) – утлы күмер алу өчен махсус кыскыч.

[2] Уармак (*диал.*) – шаяру, шау-гөр килү, ыгы-зыгы килү.

## 4

Кар китте, сукмаклар төште. Мин хәзер урамнан кайтып кермим дә. Аскы урамда Кирушлар турында атау, җир иң әүвәл шунда ачыла. Җыелышып тәтәйле[1] уйныйбыз, кузналы, акча чөябез. Кичләрен мөгәҗи амбары тирәсенә яшьләр җыела. Кайчагында яшьләр уены безнең турга – Әндриян дәдәйләрнең амбары алдына күчә. Имәнле урамыннан, гармунын күтәреп, Чыжык Бәчелие килә. Уйныйлар, җырлыйлар. Әтинең иске пинжәген иңемә салып, төренеп, мин дә бер читтә басып торам. Яшьләр җырына кушылып иреннәрем кыймылдый, ни гаҗәп, берзаман мин яшьләр җырлаганның сүзләренә үз такмакларымны кушып җибәрәм.

Яз – бәйрәмнәр чоры. Беләм, озакламый Олы көн килеп җитәчәк. Олы көн – урысларның Пасха бәйрәме. Ул көнне Баграж – керәшен авылы гөр килеп торачак. Караңгылыяктылыда бала-чагалар күкәй җыялар. Өйгә кергәч, тиз-тиз: «Иусус Кристус терелеп торган»,– диләр. Йорттан йортка йөреп, минем дә манган күкәй җыясым килә. Тик мине әни чыгармый: «Без – татар, мөселманнар»,– ди ул. Мин аңлап бетермәсәм дә, татар икәнлегемне, керәшеннәрдән аермамны сизә башладым. Су коеныргa буа алдына төшсәк, малайлар миңа карап җыр-җыр көләләр, усалраклар:

Татар, татар – тарама,
Кермә безнең арага.
Кысылырсың, үләрсең –
Биш тиен акча түләрсең,–

дип, җыр әйтәләр.

Усал малайларның авызын томаларлык такмак чыгарасым килә, барып кына чыкмый, җавап итеп кайдадыр отып алган җырны кабатлыйм:

Керәшен, керәшен – керкәле,
Баш түбәсе серкәле.

Бәйрәм якынайганын шуннан сизәм: көн туды исә, Багражның кынҗыр кызлары әни янына күлмәк тектерергә киләләр. Бәйрәм якынлашканын бер сылу кызлар гына сизәме?!

---

[1] Тәтәйле (*диал.*) – балалар уенының бер төре.

Югары очта Җәмәй атлы бер бик фәкыйрь кеше бар иде. Кышын тәмәке төрергә газета каян алгандыр, һәр язда исә ул безгә килеп керә торган иде. Килә, болдыр баскычына утыра, дәшми – теле юк. Телсез Җәмәй дә диләр, кушаматы – Пружин. Озын чандыр гәүдә сорау билгеседәй бөгелгән. Очлы иягенә өч-дүрт бөртек сакал ябышкан. Өстендә алагаем дәү якалы, терсәкләре ямаулы чикмән. Кырык ямаулы чалбар тишекләреннән тез башлары күренеп тора. Аягында киндерәләре ялганган дәү-дәү мыеклы чабаталар. Пычрак аягы белән өйгә керми, кат-кат чакырсаң да, ияген як-якка чайкый. Тәмәкегә газета сорап килгән Җәмәйне безнең әни берчакта да ашатмыйча, тамагын туйдырмыйча җибәрми торган иде. Өйдә нинди ризык пешсә, тәлинкәгә салып, Җәмәй дәдәйгә чыгара. Мин аның ашаганын карап торырга яратам. Озын җәпле бармаклары катып, калҗаеп беткән; тырнаклары – җитү. Алдына ризык килгәч, ул кинәт үзгәрә, гәүдәсе тураеп киткәндәй була. Ул ризыкны, бер бөртеген, бер тамчысын да исраф итмичә, кадерләп, олылап ашый. Ипи, дурычмак[1] өлешен йоткач, башын артка ташлый, бугаз алмасы бүлтәеп чыга, ул керфексез яшел күзләрен йома, күз урынында вак җыерчыклардан хасил елмаю гына балкып кала.

Тәлинкә чыгарасыңмы, табакмы, табамы – ризыгы беткәч, ул һәрберсен ипи катысы белән ышкый-ышкый сөртә, майга манчылган икмәк катысын кәнфит суыргандай суыра... Кулына газета эләккәч, тәмәкесен шартаякның тубырлы башы юанлыгы итеп төрә. Безнең өй тирәсендә кабызмый, әнинең тәмәке исен яратмавын белә, «тартмыйм, тартмыйм!» дигәндәй, тәмәкесен күз югарылыгына күтәреп күрсәтә.

Әниләр кая киткән булгандыр, беркөнне әбәдтән соң Җәмәй дәдәй килеп керде. Әнвәр түти ишегалдында, кояш күзенә мендәрләрне тараткан, мин, җиз тасны аударып, астына баулы таяк кыстырып, тас астына җим сибеп, күгәрчен тотарга маташам. Күгәрчен белән мавыгып, Җәмәй дәдәйне онытып җибәргәнмен, берзаман карыйм, утыра да утыра теге, ыңы-шыңы юк, тез тишекләрен чикмән итәген кайтарып яшергән. Әнвәр түти тегеңә берни чыгармый. Мин

[1] Дурычмак (*диал.*) – әче камыр җәеп, өстенә изелгән бәрәңге, орлык ягып пешерелгән ашамлык.

анын янына йөгереп килдем. «Бетмәс монда әрәмтамак, хәерчеләр!» – ди тутам. «Ипи кыерчыгы алып чыгам!» – дип, өйгә керә башлаган идем, түти мине эләктереп алды. «Йөрмә!» Мондый кирелеген белми идем тутабызның, аптырап киттем. Җәмәй дәдәй утырды-утырды да бөгелеп, бөкрәеп чыгып китте. «Саран бака син, Әнвәр түти!» – дип кычкырганымны сизми дә калдым.

Хәерчеләр дигәннән, без бәләкәй чакларда хәерчеләр авылдан авылга ел әйләнәсенә йөриләр иде. Ни бирсәң дә алалар, иске-москы кием-салымны да алалар, ипи кыерчыгына да бөгелә-сыгыла рәхмәт әйтәләр. Сәер, җәенке арбаларына утырып, дөя җиккән кыргызлар килеп чыга иде. Алар дөяләрен урам уртасында туктаталар, үзләре өй борынча кереп йөриләр, чыбыркы сабы белән муеннарын кашып: «Яндык, казалы булдык», – дип, күзләреннән кысып кына тонык тамчылар чыгаралар.

Керәшеннәр – үтә ярдәмчел, мәрхәмәтле кабилә. Кыргызларга ышаналар, жәллиләр, «бала-чагаң күпме?» дип белешәләр. Яртышар капчык бәрәңге, подаука төбенә салып он чыгаралар, ашарга да дәшеп кертәләр. Ә без, аю мае сөрткәннәрмени, дөя яныннан китмибез. Якын барырга базмыйбыз, дөянең усаллыгын беләбез. Лач итеп төкерергә дә күп алмый ул!..

Авылда тагын бер сәер хәл булды: тазарак тормышлы йорт хуҗаларын, өйләреннән куып, мунчаларга, таш амбарларга чыгардылар. Бездән ике-өч өй аркылы гына яшәгән Үтәми дәдәйләрне дә мунчага кудылар. Ишле балалы Үтәми дәдәйнең өен мәктәп иттеләр. Тиздән, бик тиздән Үтәми дәдәйнең улы – яшьтәшем Бәчели белән алар өендә беренче класста укый башларбыз дип кем уйлаган...

## 5

Без яшәгән йорт хуҗалары Багражга кайттылармы-юкмы – хәтеремдә калмаган. Әндриян дәдәй хатыны, ике малае белән Федот детдомында озак кына яшәде шикелле. Кайтмый калмаганнардыр, алар үзара да, күрше-каршы белән дә тату, дус яшәрлек сабыр, акыллы кешеләр иде. Кайтып,

безнең тигез генә аккан тормышка бер-бер бимаза ясасалар, ихтимал, хәтеремдә дә калыр иде. Явызлыкның ташка язылып, яхшылыкның комга язылуын аңлый башлаган идем инде мин. Әндриян дәдәй тәбәнәк, базык кеше иде. Бер кулының дүрт бармагы юк, кыска, кисек буынлы бармаклары белән аркамнан сөеп куркытканы исемдә. Бөдрә йомшак чәчле иде без торган йортның хуҗасы. Багражда һәркемнең нәселдән күчеп килгән кушаматы бар. Әндриян дәдәйләрнең күршесе – Боярлар. Ата-бабасы тимерче бу крестьяннарга ник Бояр кушаматы тагылгандыр, белмим. Авылның Югары очтан Түбән очка кадәр өйдән өйгә сикереп күчә торган кушаматлар әлифбасы бар, әйтик: Әндриян – Бөдрә, «Бояр ыштанын салып йөгерә...» Нәсел-нәсәбеңнән берәү авылга яки авыл кешеләренә яманлык кыла икән, беттең, кара сакалың, кая барсаң да, артыңнан калмас! Берәр адәм хәтерли микән Югары Багражның кушаматлар әлифбасын? Ялкауларга, аңкауларга, җыбыткыларга, канчыкларга[1], биләмчеләргә, каруннарга нык эләгә иде ул җор тезмәләрдә!

Нигә Бояр кушаматы алган нәселне ыштан салдырып йөгерткәннәр? Белмим. Ул нәселдән авылда байтак гаилә бар иде, һәммәсе һөнәрманнар, яхшы, тырыш кешеләр. Бояр Ибаны, яшьтәшем, исәнме син? Кайларга китеп югалдың?

Әндриян дәдәйләргә кунакка барып кайту вакыйгасы онытылмаслык булып хәтердә сеңеп калды. Сөенечле дә, фаҗигале дә булды ул хәл.

«Барып кайтыйк, булмаса, ничә тапкыр чакырдылар инде!» – дип, өйдә сөйләшенгән сүзләргә игътибар иттем: кунакка бару балачакның бәйрәме иде бит! Кунак дигәндә, мин бик җәһәт идем. Яңа юллар, ят авыллар, яңа җирләр... Һәммә тараф серле, кызыклы. Ә мин сергә тартыла торган тере малай идем. Ниһаять, сүз, күчә-күчә, төп мәсьәләгә дә барып җитте: «Өйдә кемне калдырырга? Мал-туарга, йорт-җиргә кем күз-колак булыр?» Әнвәр түтине ашыгыч кына чакырып алдылар. Чакырган җиргә килми каламы безнең тәмлетамак тутабыз? Нәни төенчеген тотып, ипләп атлап, кичкырын килеп тә җитте. Мин, авызымны ерып: «Ә без Әндриян

[1] Канчык (*диал.*) – хәрәкәтләрендә тыйнаксыз, күзгә ташланырга тырышучан хатын-кыз турында.

дәдәйләргә кунакка барабыз!» – дип кычкырдым. Әнвәр түтигә сыер савуны тапшырып булмый, сыер малы аны санга сукмый. Күршебездә үтә уңган, ишле балалы Ипис түтиләр яши. Олы эшләрне аңа тапшырып, вак-төяген Әнвәр түтигә йөкләп, ниһаять, без ерак юлга чыктык.

Федотка бездән ике юл бара икән, берсе – район үзәге Зәй аша, икенчесе аулак, урау юллар аша – Ашыт, Әхмәт, Кадер авылларын үтеп барырга кирәк. Имәнле урамын узып Түбән авылга төшеп барганда, әти белән әни әз генә тарткалашып алдылар. Әти: «Зәй аша барыйк, анда юл ышанычлы»,– дигән иде, әни каршы төште: «Әллә кайдан уратып йөргәнче, турыдан гына чыгыйк»,– ди. Әти: «Әйләнечтән юл туры, урман юлларын белмисеңмени?» – дип, үз сүзен куәтләде. Ата-аналар тарткалашканда быткыч[1] балалар тик тора аламы? Азат, дилбегә тотып, кукраеп кузлага утырган. Борыны чөенке олы малай әти ягын куәтләде: «Зәй аша барабыз, Зәй аша!» Ә мин, әни малае: «Урман аша барыйк, урман аша!» – дип тыкырдатам. Әни алдына җайлап яткан энекәшем Алмаз юлга чыгуга тәмле йокыга талды. Түбән авылга төшкәнче бәхәс дәвам итте, ахыр чиктә ике як та, йомшап, уртак фикергә килделәр: Ашыт, Әхмәт авыллары аша барабыз да Зәй аша кайтабыз! Азат, миңа борылып, телен чыгарып күрсәтте. Нигә очынган була инде, икебезнең дә сүзе үтте ләбаса!

Без Түбән авыл урамына барып кердек. Күрше авыл кешеләре, әти-әнине танып, түбәнчелек белән сәламлиләр, кая баруыбыз белән кызыксыналар, белгәч, безгә хәерле юл телиләр. Авыл кибете яныннан үткәндә, әти атны туктатты һәм, вак-төяк булмасмы дип, кибеткә кереп китте. Ары-бире каранып утырганда, күзем бер адәмгә төште. Бер йорттан чыкты да, селлин-селлин[2] атлап, икенче капкага кереп югалды ул кеше. Әз генә вакыттан соң чыкты, тагын күздән китеп торды. Җәмәй дәдәй! Өй борынча нишләп йөри икән Түбән авылда? Мин күргәнне әни дә күрә икән, сораулы карашымны абайлап: «Җәмәй дәдәң өй борынча хәер сораша, тамагын шулай туйдыра»,– дип аңлатып бирде. Җәмәй дәдәйне кызганудан җылап җибәрдем. Мин аның ничек яшәвен, ничек

[1] Быткыч – вакчыл һәм бәйләнчек (кеше).

[2] Селлин-селлин – алпан-тилпән.

тамак туйдыруын, кемнәр белән торуын моңарчы бөтенләй белмәгәнмен икән! Әни нидер аңлатты,ниләр сөйләгәне хәтеремдә калмаган, мин: «Җәмәй дәдәйгә ашарына бирик!» – дип, әнине йолыккалый башладым. Әни күчтәнәчкә төрелгән ризыклар арасыннан үзе пешергән шадра печеньены учы белән тутырып алды да миңа сузды: «Бар, улым, Җәмәй дәдәңә бир!» Тыгыз коймалы урыс капкадан чыгып килүче бичара телсез каршысына йөгердем, ташка абынып егылдым, печеньеларны күкрәгемә кыскан идем, алар чәчелмәде, кулым буш булмаганга, борыным белән җиргә бәрелдем, канады. Канаса да җыламадым.

Җәмәй дәдәй биленә таккан капчыгына печеньеларны шудырды да дәү кулы белән аркамнан какты. Сирәк сакалын селкетеп рәхмәт укыды. Аның керфексез яшькелт күзләреннән күз яше кысылып чыкты...

Әни ап-ак кулъяулыгы белән минем тузанга, канга буялган борын тирәләрен рәтләп торганда, әти кибеттән чыкты, без сәфәребезне дәвам иттек. Авылны чыккач кына, әни, миңа карап: «И улым, дөнья йөзендә бәхетсезлекләр бик күп шул әле»,– диде.

Әти белән әни үзара сөйләшеп бардылар, иген уңмаган елларны, мин аңламаган налогларны, кысуларны телгә алдылар. Җәмәй дәдәй белән очрашу аларга шулай тәэсир иттеме, әллә мондый күңелсез әңгәмәнең бүтән бер сәбәбе бар идеме? Без урманны чыктык, авыл араларын үттек, авылларга кердек, туктап ат эчерттек, әни коега су алырга килгән ят апалар белән тиз-тиз нидер сөйләште, әмма ата-анамның йөзеннән моңсулык Федотка барып җиткәнче китмәде. Бу юлы әти-әни сөйләшкән сүзләр берәм-берәм минем күңелемә кереп ояладылар. Әниемнең: «И улым, дөнья йөзендә бәхетсезләр бик күп шул әле»,– дигән сүзен мин гомерем буе онытмадым.

Бу сүзнең хак икәнлегенә тагын бер мәртәбә шунда, Федотта ук ышанырга туры килде.

Хуҗалар безне искиткеч җылы каршыладылар. Олыларга гына түгел, безгә, бот буе малайларга да сый-хөрмәтнең игечиге булмады. Пилмән дә пешерделәр, тавык та куырдылар. (Дөрес, тавык боты олы малай Азат белән төпчек малай Ал-

мазга эләкте, мин муен кимереп калдым.) Әндриян дәдәйнең уллары Никипар белән Ибан безгә элек алпавыт утары булган детдом биналарын, таллар арасында җәелеп яткан тирән буаны күрсәтеп йөрделәр. Тоташ чия агачлары белән капланган бик биек тау башына менгәч, мин телсез калдым. Мондый киңлекләрне, ерак офыкларны, матурлыкны минем берчакта да күргәнем юк иде. Баграж тавына менгәнем бар, ләкин безнең авыл өч яктан урманнар белән әйләндерелеп алынган да, тау башыннан ерак офыкларны күреп булмый торган иде. Ә монда исә... бер-берсен кисешкән басу юллары, елга буе әрәмәләрен чәлмәштергән сукмаклары мине тәмам хәйран калдырды. Кышкы карда куян эзе сыман чәлмәшкән шул сукмаклардан тагын әллә кайларга барасым, әллә нинди ят дөньялар белән танышасым килде...

Ничә көн кунак булганбыздыр, исемдә калмаган, кичләрнең берсендә өстәл тирәсендә олылар белән, тәмләп, бәрәңге дурычмагы белән чәй эчеп утыра идек, кече яктан дурычмак өйгән тәлинкә күтәреп чыгып килүче апа лып итеп урындыкка утырды. Кызганычка каршы, Әндриян дәдәй хатынының исемен онытканмын... Урындыкка утырды, тәлинкәсе идәнгә шапылдап төште, майлы дурычмаклар идәнгә тәгәрәде. Олылар: «Ни булды? Ни булды?» – дип, апа тирәсендә кылбырдак[1] килделәр. «Башыма кемдер күсәк белән китереп сукты!» – диде апа, әз-мәз хәлен җыеп. Олылар дару эзләргә тотынды, мин тәмам аптыраашта калдым. Нинди күсәк? Кем сукты? Өйдә бездән башка беркем дә юк лабаса? Уллары Никипар белән Ибан да өйдә юк. Алар Зәйдән килгән кунак абыйны буа койрыгындагы камышлыкка үрдәк атарга алып киткәннәр. Кичке чәйгә алар да кайтып җитәргә тиеш. Апабыз җылапмы-җылый, бәргәләнә генә, чыдый алмый. Әндриян дәдәй чакыруы буенча, бераздан өйгә фельдшер килеп керде. Биргән даруларны эчмәде Әндриян дәдәйнең җәмәгате, гел бер сүзне кабатлады: «Бәла килде безгә, хәсрәт килде. Башыбызга кайгы төште!»

Эңгер-меңгер иңгәндә, кабык арбага салып, Әндриян дәдәйнең кече улы Ибанның җансыз гәүдәсен алып кайттылар... Эш болай булган икән. Зәйдән килгән сунарчы ка-

[1] Кылбырдак (*диал.*) – ыгы-зыгы, тәртипсез эш-хәрәкәт.

мышлар селкенгәнен абайлаган да шул төшкә төбәп атып та җибәргән. Ядрәләре туп-туры Ибанның күкрәгенә килеп төшкән икән, йөрәгенә үтеп кергән. Ибан аһылдап кычкырган да шунда ук җан биргән... Шул секундта әнкәсенең башына күсәк белән органдай булган. Ана сизгерлегенә тиңнәр юк!

Әндриян дәдәй сап-сары нарат такталардан улына табут ясый... Нарат ылыслары белән, чәчәкләр белән бизәлгән караватта Ибан ята. Аның баш очында кара яулыгын бәйләгән әнисе утыра. Ишегалдында ике кулын аермаска йозаклап, һавада селки-селки, бичара сунарчы – Әндриян дәдәйнең кардәше йөри. Өй тирәсендә йөзләгән детдом балалары җыелган. Бүтән чакта шукланырга, төрткәләшергә һәвәс малайлар да бүген тып-тын торалар.

Мин дә шулар тирәсендә йөрим. Мин бүген фаҗиганең ни икәнен, ата-ана хәсрәтен беренче тапкыр үз күзләрем белән күрдем. Хәзер буа өстендәге тип-тигез су да, биек-биеккә менеп киткән таулар да, буа өстенә ишелеп торган агачлар да, алпавыт утары, ул яшәгән йорт болдырының түгәрәк, сырлы-сырлы бизәкле баганалары да күземә күренми. Болытлымы көн, кояшлымы – барыбер караңгы...

Ибанны ничек, кая күмүләре исемдә калмаган. Кайсы юлдан кайтканыбызны да белмим. Хәер, моның әһәмияте бар идемени хәзер? Әче күз яшьләренә төрелгән бу көн, нарат ылыслары арасында сузылган Ибанның балавыздай йөзе, Җәмәй дәдәйнең йорттан йортка кереп теләнеп йөрүе шушы җәемнең иң авыр хатирәләре булды шикелле.

Ибан үлгәч, Әндриян дәдәйләр Федот детдомында озак тормадылар, Багражга кайттылар. Без гаиләбез белән Урта урамның буш өенә күчтек. Аның хуҗалары кая киткән булгандыр, хәтерләмим, мәгәр аларны да бер-бер нужа, бәхетсезлек күчереп йөрткәндер дип уйлыйм. Кешеләрне урыннан урынга күчәргә мәҗбүр иткән тынгысыз заманга кереп баруыбыз хакында әти-әниләрнең кеше югында шыпырт кына сөйләшүләре истә калган...

*Займище*

*1991, июль–август*

## Дөнья агышына без бер буын булып килеп кердек[1]

*(«Урталыкта», повестьтан өзек)*

Дөнья агышына без бер буын булып килеп кердек: яшьтәш кызлар, яшьтәш малайлар... Мең тугыз йөз егерме сигезенче елда туганнар. Борынгыча әйтсәк, Балык елында туганбыз без.

Онытма: туфракның бер катламы, агач кәүсәләрендәге бер сыр безнеке булды. Дөнья тарихының бер елын без туган елыбыз иттек.

Күр: үстек, аякка бастык, тернәкләндек.

Кешеләрнең язмышы бер-берсенекенә охшамаган кебек, буыннарны да үзләренә генә хас, үзгә язмыш көтә...

Бел: безнең юлга гөл сибеп куймаганнар иде!

Әтиләр, абыйлар мылтык тотып, кылыч тагып Ватан сугышына чыгып киткәндә, без бәхетле мәктәп балалары идек... Безнең бәхет бер көндә, Гитлер тупларының тавышы астында җимерелде. Җирдә сугышлар күп булган, әмма кайсы буын шундый дәһшәтле, миллионлаган корбаннар алган сугышны кичергән?..

Без ятим, тол әниләрнең сыңар канатына сыенып үскән малай-кызлар. Сугышның утлы сулышы нәкъ безнең елгыларга килеп җитеп тукталды, егерме җидедә туганнарны кырык дүртнең декабрь аенда без сугышка озаттык... Ә безгә өч-дүрт ел буе никрут булып йөрергә язган иде... Берничә ел армиягә призыв булмады.

Без...

Малайлар, кызлар...

---

[1] А. Гыйләҗевнең 1969—1970 елларда язылган повесте. Әсәрнең ике редакциясе сакланган. Беренче варианты, 1969—1970 елларда иҗат ителеп, 1972 елда «Казан утлары» журналында (№ 8) басыла. Шул ук елны «Кызлар хатлары» җыентыгына да кертелә. 1972 елда әдип әсәрен икенче мәртәбә эшләп чыга һәм «Современник» нәшриятында басылачак «Девичьи письма» җыентыгына тәкъдим итә. Ләкин тәрҗемә вариантын әзерләп өлгертә алмыйлар. «Посередине» исеме белән 1979 елда чыккан «Любовь и ненависть» җыентыгына гына кертелә. Алга таба әсәрнең икенче варианты «Мең чакрым юл» (1978) һәм «Сайланма әсәрләр» (1994, 2002, 2015) җыентыкларында дөнья күрә.

Сөйкемле яшьтәшләрем минем! Безнең гомер сукмакларын онытмадыгызмы?

Дөрес, без ипине утыз яшькә җиткәч кенә туя ашадык... Шоколадны беренче тапкыр егерме биштә татып карадым мин, морожныйны иртәрәк – егермедә. Шампан шәрабын – утызны узгач кына!..

«Дөнья бирде кирәкне!» – дип, шагыйрь безнең турыда язды.

Бусы әле бераз соңрак, еллар узгач...

Әлегә уртак язмыш:

– Җилкәләрдә йөргән авыр капчыклар, саллы чи бүрәнәләр, күмер тутырылган вагоннар ул – без!

– Үзебез сабанга җигелеп сөрелгән әремле кырлар ул – без!

– Станокларга буебыз җитмәгәч, бүкәнгә басып көне-төне тимер кырган ул – без!

– Чи утын ягып, пыш-пыш килеп көне буе барган, инә буе җир киткән пароходлар ул – без!

– Ягылмаган класслар, дәфтәр урынына саргайган газета битләре ул – без!

– Кичә генә безнең белән парта арасында утырып, бүген укытучы урынын алган үсмерләр ул – без!

– Әниләрнең ябык куллары, яшькә манчылган зур күзләре ул – без!

Нужа кешенең башын эшләтә, без бик иртә ир булдык; ир булгач инде җылашмадык, бирешмәдек, сатылмадык, зур Җиңүне яулаштык. Без аз сүзле идек, кырыс идек, нык идек.

Без бик зур вакыйгаларга шаһит: без яулаган Җиңүне тарих мәңге онытмас!.. Ачы-төчене дә мул татыдык, әмма барын да бүлештек. Хаксызга рәнҗетсәләр дә үпкәли белмәдек. Без тормышны олы кешеләрсез төзи башладык, олылар анда, еракта, утлы окопларда иде. Алар безнең төшкә генә керәләр иде, мөгаен, без дә аларның йокыларын аз бүлмәгәнбездер... Тик төштә генә күрешүләр – иң аяныч күрешүләр алар!

Без, абына-сөртенә, алга бардык, тормыш кануннарын үзебез ачтык. Тәҗрибәбез булмаса да, без туры юлдан тайпылмадык... Сугыштан соңгы авыр елларда бер тапкыр да «аһ» димәдек...

Безнең күзләр күпне күрде. Авторитетлар, ярым аллалар, без табынган затлар пьедесталлардан безнең алда чәчрәп төште. Тугрылыкның, хаклыкның бәясе бермә-бер күтәрелде.

Боларның барысын да бер күңелгә сыйдырып бетерү, аңлау, аңлату читен булса да, без бирешмәскә тырыштык...

Тормыш дулкыннары безне, беләкләре ныгып килгән егет-кызларны, күнегелгән авыл нигезеннән куптарып, зур калаларга алып килде. Исеме телгә кермәсә дә, фән-техника революциясе башланган чак иде. Кәҗә бәрәннәре, сарык бәтиләре, ак муенлы көчекләр белән аунап үскән, ананаслар, әфлисуннар түгел, кәҗә сакалы, балтырганнар, көпшәләр ашап кинәнгән малайлар беркөнне кала абзыйларына әйләндек.

Авылда барысы да бик гади кебек иде.

Үткәннәр әнә алар, ап-ак ташлар булып, зират өстендә тезелешеп утыралар... Ташлары да Каф тау артыннан килмәгән, әнә шундагы тәбәнәк тауларның бәгыреннән алынган...

Туган ил, туган җир төшенчәсе аермачык иде.

Менә синең туган илең:

– Тыкрыкларга сыймый каңгылдашып кайткан ак казлар...

– Көзге урман юлларында тәгәрмәч эзләреннән йөгерешкән сары өрәңге яфраклары...

– Кышкы озын кичләрдә, җылы мунчаларда йөзек салыш...

– Сабан туенда җир гүелдәтеп чабышкан атлар...

– Мәктәп музеенда утызынчы елларда межада канга буялган кызыл әләм...

Бабайлар, әтиләр шулай яшәгәннәр...

Авыл белән шәһәр ул чагында бер-берсеннән бик ерак торалар иде, тормышларында аерма бик зур иде.

Без, чабаталы авыл малайлары, бер мәлгә аптырашта калдык. Берәүләр сыгылдылар, берәүләр егылдылар, берәүләр яраштылар, берәүләр югалдылар ук...

Без таралыштык һәм яңадан бер-беребезне җыеп ала алмадык...

Бәлки, бу кичерешләр минем баштан гына узганнардыр?

## Сүз ачыклагычы өчен аз-маз хатирәләр[1]

*(«Шәһәр юллары авылга илтә», очерктан өзек)*

### 2. Сүз ачыклагычы өчен аз-маз хатирәләр

Җырга-моңга бай, зәңгәр таулы Сарман районының шактый усал исемле Чукмарлы авылында тусам да, әтиемнәр утызынчы елда Зәй районының Югары Баграж авылына күчеп килгәннәр, кырык дүртнең көзенә хәтле мин шунда яшәдем. Өч яктан да бәрәкәтле куе карурманнар белән уратып алынган, районның иң читендәге шушы керәшен авылы минем бала чагымның бишеге, яшьлегемнең кызыклы нигезе булды. Тимер юлдан – йөз ун, су юлыннан алтмыш чакрымнар ераклыкта качып утырган бу авыл, үзе бер мөстәкыйль дәүләт кебек, күрше-тирә белән, киң дөнья белән артык аралашмыйча, үз төсен саклап яши иде кебек. Авылның көнчыгышыннан тибеп чыккан нәни генә инешне багражлылар, зурлап, Олы су дип йөртәләр, безнең, чыннан да, шул инештән олырак суны күргәнебез юк иде! Инеш аръягында – болын, болынның теге ягында саз-баткаклыклар башлана, куе яшькелт мүк тирбәлгән дәү келәмгә йомры-йомры түмгәкләр сибелгән, түмгәк саен тәкәрлек оясы...

Сазлык – безнең иң яраткан уен урыныбыз. Яздан көзгәчә монда без хуҗа: селкенеп торган түмгәкләр арасында шау-гөр килеп качышлы уйныйбыз, йомшак, җылы мүклектә пәкеле уйнау да рәхәт, шунда ук чәкәләшеп тә алабыз. Сазлык тирәсендә безгә эш тә җитәрлек – мүк йолкабыз, аны әйләндерә-әйләндерә киптерәбез, бәләкәй арбалар белән ихаталарга ташыйбыз, анда-санда ялтырап яткан күлләргә киндер көлтәсе салабыз, аны батырабыз, чыгарабыз, таратып киптерәбез. Инешкә табарак урыннарда Баграж хатыннары, ярыша-ярыша, киндер талкыйлар. Ир-атлар, күлләрне сасытып, юкә сала. Без, авыр, дымлы кабыкларны сөйрәп чыгарып, яр буенда ук мунчала каезлыйбыз. Баграж крокодиллары – авыр-авыр калын кабыклар – әле дә булса күз алдымда... Яр буйларында,

[1] А. Гыйләҗевнең 1983 елда язылган «Татарстан могҗизасы» исемле очерклар китабы. Беренче тапкыр «Казан утлары» журналында (1981, № 10) дөнья күрә. 1985 елда Татарстан китап нәшриятында китап булып басыла.

безне үртәп, олы күзле бакалар сикерешә, беркатлы, гөнаһсыз авыл уйлары тулган баш очыбыздан, чыелдый-чыелдый, тәкәрлекләр оча. Бик биектә, зәңгәр күктә, нурлар кисешкән урында, тилгәннәр тирбәлә. Инеш аръягыннан җәен-кышын кеше өзелми. Бөтен йорт кирәк-яракларын, тормыш, хуҗалык нәрсәләрен, ат-туар дирбиясен Баграж кешеләре үзләре җитештерә, кышын һәркемнең өстендә билле кара яки сары кайры тун, безнең авылда тегелгән толыпларга төренеп кашавай түренә чумып утырсаң, якут ягы салкыннары да куркыныч түгел! Колхозның ныгыган чагы, икмәкне кызыл олаулар белән өй борынча таратып йөриләр, көз җитте исә, балын, кәбестәкишерен хезмәт көненә бүлеп бирәләр, андый көннәрдә авыл гөрләп тора, тормыш бөтен, тормыш түгәрәк, табын ашлысулы, хәлләр һәр өйдә дә көйле диярлек иде. Мал-туарны мул асрыйлар, көтүлекләр күп, болын печәнен кыркыгач, сыерсарыклар паҗбыга – урман кишәрлекләренә утлауга керәләр, анда инде кая карама – билдән печән. Тире илиләр, итек басалар, тула, чикмән киезен баса беләләр, ярлы-ябагайның өстендә дә яңа чикмән, искитәрлек! Киндер станында сугып, күлмәк-ыштанны да зәңгәргә манылган алачадан тегәләр, күлмәкләр бәбәйтәкле, шәлне дә кәҗә мамыгыннан үзләре бәйли, пирчәткә-бияләйне әйткән дә юк, тоз белән «кырачин» кайтып торса, багражлылар үз хуҗалыклары белән рәхәтләнеп, дөньяның артына тибеп яшиләр. (Ара-тирә көмешкә кайнатсалар да, сугышка кадәр безнең авылда аракы эчү бик чамалы иде, исерекләр бөтенләй юк иде!) Агач клуб (элек чиркәү булган, аның ике манарасын кисеп, хачларын гөрселдәтеп җиргә төшерүләрен әле дә хәтерлим!) гөрләп тора, спектакльләрне авыл яшьләре куя, мәктәп зур, укытучылар һәр эшне башлап йөри, безнең атаклы гармунчыларыбыз, гөсләчеләр, скрипкачылар, җырчыларыбыз, биючеләребез бар иде...

Ватан сугышы безне бик тиз олы дөньяга алып чыкты...

Сугыш елларында без үсмер егетләр идек. Сугыш елларында үсмер егет булу – бик зур җаваплылык ул. Үсмер егет – авылда бердәнбер өмет. Тыныч елларда ата канаты астында иркәләнеп кенә яшәгән үсмерләрне сугыш бер селтәнүдә олы кеше ясады. Төп көч. Колхозның бөтен ышанычы синдә. Эшнең авырлыгы – синең җилкәгә. Эшнең иң читене – без-

нең өлешкә. Кырның һәр сукмагы, олы дөньяга чыга торган Баграж–Зәй–Чаллы юлларының һәр бормасы безгә таныш. Фронтка әтиләрне шушы юллардан озаттык. Абыйлар да шуннан китте. Яралылар, култык таяклары белән ерак чакрымнарны үлчи-үлчи, шушы юлдан кайтты. Әни-апаларыбыз шушы юлдан Чаллы базарына йөрделәр, өшәнчеккә килгән күлмәк-күнчекләрен тоз, керосинга алыштырып, безнең гомерләрне саклап калдылар. Пристань тирәсендә хәрәкәт зур, акмаса да тама, бер бүктәр әйбер күтәреп китәләр дә, кысыр сыер җилене хәтле янчыкка тутырып, тоз алып кайталар. Юк, кәнфит-прәннек түгел, тоз! Сельпога – товар, МТСка бензин-керосин, солидолы-башкасы, кыскасы, Багражның гына түгел, районның бөтен кирәк-ярагы шушы юлдан кайта иде.

Зәй–Чаллы арасы...

Күпме ачы тир, канлы күз яшьләре тамган юл ул. Күпме аһ-зар, ничаклы шатлык-өмет авазлары яңгыраган юл ул. Зәй–Чаллы юлы безнең асыл гомернең бик күп вакыйгаларына шаһит! Үкчәләре ашалып беткән кирза итекләр, күпне күреп чачакланган солдат ботинкалары, мыеклы чабаталар киеп, без бу юлның һәр квадратында үзебезнең тирән эзләребезне калдырдык. Фронтка без икмәкне шушы юлдан ташыдык. Язын чәчүлекнең байтак өлешен шушы юллардан алып кайттык. Баграждан Чаллыга турырак та юл бар, Кабан–Бастырык, Шыкмай, Борды авыллары аша барсаң, күпкә туры, әмма чак кына яңгыр сибәләп китсә дә, җәй буе череп яткан урын-юлларга кererлек түгел, муеннан саз, шуңа күрә, «әйләнечтән юл туры» дип, Чаллы элеваторына да Зәй аша йөрибез. Анда, ичмасам, «шоссе», кайчандыр таш җәелгән булган...

Атлар арык, арбалар иске, кырылып беткән күчәрләр майланмаган, капчык-чыбылдыклар кырык ямаулы. Тамак һәрвакыт ач диярлек... Ә йөзебез барыбер якты, күңелләр күтәренке, без зарлана да, зарланганны хуплый да белми идек. Арба чәкүшкәсеннән чак кына калкурак малайлар, нәзек беләкле үсмерләр, «эһ» тә итмичә, караңгы төннәрдә, үзәк өзгеч көзге җилләрдә, икмәк төяп, шушы юлларга бер карышусыз чыгып китә идек. Юлдашларымның якты хатирәләрен, эшчән яшьлегебезнең мәшәкатьле көннәрен мин байтак әсәрләремдә ачарга тырыштым. «Дүртәү», «Берәү», «Язгы

кәрваннар» повестьларының күпчелек геройлары — чын, тормышта булган, үзем белән янәшә яшәгән кешеләр. Әйе, мин озын юлларда да, кара төннәрдә дә, чыклы таңнарда да алар арасында. Чын кешеләр, дим, бу сүзне авыз тутырып, моңсу горурлык белән әйтәм бүген. Баграж малайлары: Әтәч Ибан, Озын Микәйлә Микулае, Баяр Ибаны. Без дүртәү... Безнең янда Баграж толлары, Баграж җиңгиләре, Баграж ятимнәре...

Без дүртәү, кемнәрдер өчкә төйнәлгән, кемнәрдер икәү, арада гел ялгызлар да бар. Авылда чакта шулай, юлга чыккач та, без бер тәнгә, бер җанга әвереләбез, бер сулышта сулыйбыз... Юлның Аксар авылы турыннан без кырыкмаса-кырык тапкыр узганбыздыр. Элегрәк монда Тәкмәк авылы бар иде, хәзер ул юк, таралган. Зәй болынына төшеп, ат ашатып төн кунганыбызны да хәтерлим, ап-ачык исемдә, әмма менә бу таучыкның Алтынтау булуын менә хәзер генә — 1980 елның көзендә — Мәгъсум Гарипович[1] авызыннан беренче тапкыр ишеттем. Бер дә алтынлы булып күренмәгән иде заманында бу теңкәгә тигән җәфалы үрләр! Теңкә корткыч чокырлы-чакырлы, ябышкак балчыклы үзәннәрнең исеме белән кызыксынмый идек без. Әллә биеккә күз күтәреп карарга мөмкинлегебез булмады микән? Гел үр дә үр, борма да борма! Чокырга чокыр тоташкан, тәгәрмәч эзләре уелып тирәнәйгәннәр, кая кермә — тездән су, лай. Күз гел эштә — әле атның ак күбеккә баткан ботларына сызланып карыйсың, әле аның ыңгырчак тиеп беткән кутырлы арык сыртына...

Йомшак, көчсез тавыш белән чөңгереп аңа көч-куәт биргән буласың, башкача мазаң юк... Түшлекне ныгытасың, аркалыкны тикшерәсең, мунчаладан гына ишелгән камыт баулары чыдармы, дип, котың очып бара. Тәгәрмәч тугымнары ашалып беткән. Кигиләре[2] төшкән... арба кендеге дә өметледән түгел, кинәтрәк борсаң, арбаң мәтәлеп авып китәчәк! Арада көчлерәк бер ат була, арбаң ныгытып ук батып калганда, тырышып-тырышып та этеп чыгара алмагач, барың да тукталасың, үз атыңны тугарып, егәрле атны җигәсең... Тездән сазга чумып, ай-һайлап, иңне арт үкчәгә

[1] Мәгъсум Гариф улы Гарипов — КПССның Зәй шәһәр комитеты секретаре.

[2] Киги — тәгәрмәч тырнагы.

терәп, арбаны этәсең. Тишек урыннан чыбылдык астына кул кереп китә, анда җылы бодай, тик син бер генә бөртекне дә алып капмыйсың... Муеннар тегәрҗеп юанлыгы гына, күз чокырлары чынаяк чокыры кебек тирән, тутлы яңаклар җәя бавы кебек киерелгән. Кая ул тауга күтәрелеп карарга, аның Алтынтау булуын уйларга безнең вакыт та, көч тә юк. Тизрәк, тизрәк, өстән коеп ява башлаганчы, атлар салкын яңгыр астында тагын да хәлсезләнгәнче, Чаллыга барып җитәргә, бөтен авыл халкы берәмтекләп җыйган (ул чагында кырда бер генә башакны да калдырмаска тырыша идек!) күз карасыдай икмәкне исән-имин хөкүмәт амбарларына тапшырырга кирәк. Бу уңайдан безнең уйлар бер, без бу турыда сөйләшмәсәк тә, теләкләр уртак, фронтка икмәк кирәген бөтен күзәнәкләребез белән беләбез. Анда мондагыдан мең читен! Җиңү анда яулана. Анда! Канлы сугыш кырларында! Ә без... безнеке – гадәти хәл, тыныч тыл, без сүзсез-авазсыз гына Зәй – Чаллы юлыннан кайтып кермибез...

Бериш тәнкыйтьчеләр безне, бертөрлелектә гаепләп, байтак вакыт тукмап килделәр. Флүн Мусин[1] минем «Дүртәү» повестена юкка ябырылды! Әлеге тәнкыйтьчеләрнең аршыннары кыска булган, урман артында ни барын күрмәгәннәр, безнең кайнар йөрәкләрнең тибешен аңламаганнар алар. Без әсәрләребез түренә үткәргән исемсез батырлар – авыл үсмерләре – дөнья таң калырлык эш күрсәткән икән ул чакта! Тәнкыйтьчеләр әнә шуларны ачасы урынга «шәкерт җиләненнән бет чүпләгәннәр». Гел кирәкмәгән җирдә казынганнар. Татар тәнкыйтенә хәзер дә хас сыйфат ич бу! Алар язучылардан шактый артка калганнар, татар әдипләренең адымын бары тик үзәк матбугатында күренеп киткән әсәрләр белән механик рәвештә чагыштырып бәя биргәннәр диярлек. Кызганычка каршы, мин үзем дә үзебезнең яшьлек юлларына чын күз белән бераз соңгарак калып карадым, ул көннәр турында кат-кат борчылып уйлансам да, фактларның нәтиҗәләрен башта ук белеп бетермәдем. Алай да «Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят»[2] по-

[1] Флүн Мөслах улы Мусин (1939–2009), әдәбият белгече, тәнкыйтьче. Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1991).

[2] А. Гыйләҗевнең 1972–1973 елларда язылган повесте.

вестьларын язганда, мин чын күңелдән бәхетле идем, чөнки намусым кушканны үтәдем. Инде байтак еллар узгач, заманында без белергә дә, танышырга да мөмкин булмаган документлар матбугатта басылгач кына, мин үз чордашларымның, юлдашларымның нинди олы һәм тиңдәшсез мөһим эш башкаруларына тагын бер кат инандым. Менә ул кыйммәтле документларның берсе:

*«Красная Армия помогает будапештскому населению продовольствием. Из справки политотдела 46-й армии о занятых Красной Армией районах в западной части Будапешта.*

*11 января 1945 года*

*Командование частей и подразделений Красной Армии оказывает помощь жителям города, снабжая их, по мере возможности, продуктами питания. Так, например, командование 305-го стрелкового полка 108-й стрелковой дивизии передало в распоряжение населения свыше 5 т хлеба, более 100 кг крупы и пр.*

*В районе расположения этого полка находится приют, устроенный шведским представительством Красного Креста для 200 детей евреев и коммунистов, расстрелянных салашистами. Приют находится недалеко от нашего переднего края и подвергается систематическим обстрелам немецкой артиллерии. Дети сидели без пищи и воды. Командированием полка отпущено для приюта 5 т картошки и свыше 400 кг мяса.*

*Начальник 7-го отделения политотдела 46-й армии подполковник Грекул».*

Менә икенче документтан өзек:

*«Выполнение решения Советского правительства об оказании помощи г. Будапешту.*

*26 июня 1945 года*

*СНК СССР товарищу Микояну А. И.*

*НКО СССР товарищу Хрулеву А. В.*

*Ваше задание о введении новых норм снабжения в г. Будапеште, согласно решению ГОКО от 19 июня 1945 года, выполнено.*

*Бургомистру города передано: зерна – 3000 т, сахара – 1000 т, соли – 960 т и 240 грузовых автомашин. Остальное зерно и мясо (скот) будут переданы городу до 10 июля в сроки по согласованию с бургомистром города...»*[1].

[1] Коммунист.– 1975.– № 4. – *А. Гыйләҗев искәрмәсе.*

Ит, май, тоз, ярма, шикәр. Икмәк!

Журналда Варшава, Вена, Прага, Белград, Берлин гражданнарын, фашист коллыгыннан кичә генә азат ителгән венгр, поляк, немец, австрия, югославия халыкларын азык-төлек, тормыш кирәк-яраклары белән ашыгыч рәвештә тәэмин итү турында гыйбрәтле, мәңге онытылырга тиеш түгел тарихи документлар теркәлгән. Документларга 1944, 1945 еллар датасы куелган.

1944, 1945 еллар!..

Хәтердә, 1944 елда без кара көзгә кадәр Чаллыга икмәк ташыдык. Икмәк! Үз авызыбыздан өзеп илттек. Без, фронтка икмәк, сөт, ит озатып, үз ватандашларыбызның тамагын туйдырып кына калмаганбыз икән! Совет солдаты Европа халыкларын фашизм коллыгыннан коткарып кына калмаган, ул аларга бөек интернационализм рухының ни икәнен чынбарлыкта, тормышта күрсәткән. Ярты илебез җимерек яткан хәлдә, тылда азык-төлек ягы ифрат кыен чакта, немец снарядлары явып торганда, безнең әти-абыйларыбыз бүленеп калган еврей балаларына, коммунист балаларына үз авызларыннан ит, икмәк илтә торган булганнар.

1944 ел!..

Хәтердә! Истә! Онытылмас та! Көз. Минем ябык кулым чыбылдыкның тишек җиреннән җылы бодай арасына килеп керә... Тик мин бер бөртекне дә авызыма капмыйм. Иптәшләрем дә шулай. Олаулардан җитмәүчелек бик сирәк чыга торган иде. Ил табынына куелган икмәктә безнең газиз өлешебез барын без тирәнтен аңлый идек. Мин хәзер ул чакларны хәтерләп горурланам. Бөек Ватан сугышында җиңүнең 30 еллыгына багышланып игълан ителгән документлар горурлык хисемне хаклы рәвештә ныгыталар, үстерәләр. Сугыштан соңгы еллар безнең иманны тагын да ачыкладылар: тамак ягыбыз кысан булса да, без көрәшә белгәнбез, җиңелмәгәнбез, батыр һәм тыйнак булганбыз. Сугыш еллары кешеләренең саф күңелләрен байтак әсәрләремдә теркәп калдыруым белән мин хаклы рәвештә мактана алам. Әле ул кешеләргә бурычымны үтәп бетергәнем юк, тагын язармын, ул елларга тагын кайтырмын дип уйлыйм...

Баграж—Зәй—Чаллы юллары!..

Үз ягыбызны чак кына кимсетеп, үз яшәешебезне аз-маз гына кечерәйтеп, юкка кыенсынып йөргәнбез! Тарихи юллар икән ич алар!

Баграж–Зәй–Чаллы юллары!..
Казан дигән каланың
Санап чыктым урамын.
«Сау бул, бәгъре!» – дигән идем,
Елап бирде кулларын...–

дип җырлый иде безнең иртә тол калган кызларыбыз шушы юлларда. Булды, җылаган чаклар да булды. Чөнки без кичергәннәр чамасыз зур, кичерешләргә кайгы-шатлыкның иң тирәннәре дә сыя иде. Без катнашкан тормыш вакыйгалары олы иде, әмма без кече күңелле булып кала алдык, җиңеп күкрәк какмадык. Нинди гүзәл сыйфат: кешеләрнең, олы булып та, гадилекне, күңел киңлеген югалтмаулары!..

*Казан, 1983*

## Тәкъдирдә язганы шул булгандыр...[1]

*(Истәлекләр)*

Беренче класста гына укыса да, кинәт үсеп киткән, нәзек, курач кызыкай Нәкыянең тездән түбән төшеп торган ак ыштан балагыннан чеметеп тартып: «Әй, кызый, минем тирәмдә бик чыркылдап йөрмә, берзаман кайтып өйләнермен әле үзеңә»,– дигән идем мин – унынчы класста укучы егет.

Ник тарттым икән ыштан балагыннан! Соңыннан, байтак еллар үткәч, язмышлар безне гомерлеккә кавыштыргач, исем китеп, еш кына уйланган мизгелләрем булды. Шул уй-фикерләремә йомгак ясап, сезгә дә ачарга булдым күңел сандыгымны, кадерле укучым...

Ир-атлар фронтта. Сугыш еллары хатын-кыз укытучыларны да кайсын кая таратып бетерде. 1944 елның көзендә мин укыган Югары Баграж урта мәктәбен дә яптылар. Мин унынчы классны ата-бабамның туган төяге Сарман мәктәбенә кайтып тәмамларга ниятләдем һәм шулай булды да.

---

[1] Гыйләҗев А. Тәкъдирдә язганы шул булгандыр... (Үзенең тормышы турында истәлекләр) // «Таһир +Зөһрә».– 1999.– №2.– Б. 4–5.

Сарманга терәлеп үк торган Югары Әхмәт авылында әнием Мөгаттәрәнең төп йорты. Ире Сөләйманны 1942 елда соңгы юлына озатып калган сөекле әбием Зөләйха хәзер йорт башы. Нык хуҗалыклы, чамасыз тырыш, мал кадерен белгән бабам дөньяны куйса да, Сөләйманнар нигезе авылда бердәнбер диярлек иде. Йорт-җир хәзер Сөләйманнарның төпчеге Мирзаһит кулында. Ул бабамның вафатыннан соңгы кышта (1942 елда) фронттан каты яраланып кайткан.

Мин Зөләйха әбиемнәрдә яшәп, Сарман мәктәбенә укырга йөри башладым. Авыл аралары якын гына, мул гына сулы Минзәлә елгасы аша салынган басманы чыгасың да Сарманга барып керәсең.

Чын татар авылын күреп калуым белән бәхетлемен! Сугышка кадәрге Югары Әхмәт татарның мең еллык кануның саклап торучы гүзәл бер авыл иде. Керәшенстан үзәге Зәй төбәгеннән килеп, Айтуган күперен чыгуга, борынга бик үзенчәлекле төтен исе килеп бәреләә. Кыр ягы исе бу, урманнар юк бу тирәләрдә. Югары Әхмәт халкы сазламыктан торф чыгарып ягулык әзерли, ел дәвамында җыелган тиресне елга буена ташып өя дә өмә ясап тирес суга. Янган кизәк исе борынгы бабаларыбызны, аларның күчмә чакларын, кылган җай гына тирбәлгән иркен болыннарны, һау-һаулап җылкы көтүләрен куган бүз егетләрне, Сабан туйларын, туклык бөркелеп торган көзге җыеннарны искә төшерә. Айтуган күпереннән Югары Әхмәткә барып җиткәнче мин әллә нинди серле, сихерле дөньяда яшәп алам, үсмер егет каны уйный, тамырлардан җитезрәк ага башлый. Менә Сөләйман бабайларның яшеллеккә күмелгән ындырлары шәйләнә, мәчетманара араларында бәхәсләшеп очкан чәүкәләрнең тавышы колакка керә. Егерме биш чакрым араны җәяү узган арганлык онытыла, абына-сөртенә ашыгасың. Саумы, Югары Әхмәт! Саумы, Уралның койрыгы булган Текәй таулары! Шул тауларның күкрәгеннән бәреп чыккан Бузат чишмәсе! Исәнме, Ялгыз каен! Йомшак эңгер каплаган тарлавыклар! Мин сезнең арагызга киләм! Букчамда китап, дәфтәрләр арасында шигырьләрем, тәүге зәгыйфь хикәяләрем дә кереп кысылган.

Монда бер нәрсәне ачыклап үтәргә кирәк. Мирзаһит абыемның хатыны Нәҗия, минем җиңгәм, кырык дүртенче

елда бәбәй алып кайткан икән, кыз бала. Сөйкемле булса да, җылаграк кызчык. Шул бәбинең бишеге тирәсендә мин җиде-сигез яшьләрдәге, тал чыбыгыдай нәзек, кара күзле икенче кызыкайны шәйли башладым. Булачак кәләшем Нәкыя шушы кыз иде инде.

Без дүрт малай үстек, гаиләбездә кыз бала күргәнем юк. Нәкыянең җиңел сөякле, үтә җитез булуына игътибар иттемме, әллә аның бишектәге бәбигә ихлас мәхәббәте сокландырдымы, әмма туганнан бирле үзен язучы итеп тойган яшь егет кызны җентекләбрәк күзәтә башлады. Нәкыя мәктәбеннән кайта да безгә йөгерә: килә, керә, бит-кулларын юып, бәби кыз бишегенә тотына. Бәби йокламаган булса, аның бармакларын берәмтекләп үбә, бәби дә аны зарыгып көткәндәй елмая, көлеп тә куйгалый. Бер-берсенә сүзсез тартылган ике җылы җанны күзәтеп, мин дә сөенәм. Сугыш елларында боеккан өй эче яктырып, нурланып китә.

Мин инде Әхмәттә күп нәрсәләр беләм. Нәкыянең әнисе – тол хатын Нәүбаһар түти белән дә таныш. Ике малаен һәм Нәкыяне тәрбия итүче бу тол хатын, ире Илһаметдин төрмәдә үлгәннән соң, йорт-җирен, хуҗалыгын менә дигән итеп алып бара. Кышлык ягулыгы да җитәрлек аның, бәрәңге-яшелчәсе дә уңа, лапас-куралары да каралган, иреннән ятим калган бал кортлары балны ташып кына торалар.

«Әнкәсенә карап кызын ал!» – дип акыл беркеткән безнең бабайлар. Яшь аермабыз шактый булса да (тугыз ел!) Нәкыягә күз салуымның төп сәбәпләре шулардыр дип уйлыйм: Зөләйха әбиемнәрнең изге нигезе, мохит, җылы күңелле ихлас татар дөньясы, бишек тирәсендәге сокланргыч гамәлләр, әнкәсенең уңганлыгы, чисталыгы, авылча аш-суга осталыгы.

Һәм көннәрдән бер көнне ачыктан-ачык, туп-турыдан мәхәббәт аңлату: «Күп чыркылдап йөрмә, кайтырмын да өйләнермен!»

Фәрештәләрнең дәррәү «Амин!» дигән чагына туры килдеме, яшьлегемдәге дуамал хыялларымның күпчелеге тормышка ашты. Мин Нәкыягә өйләнеп, без уртак тормыш корып җибәрдек. Ләкин аңа кадәр әле...

Мин Казан дәүләт университетына өч тапкыр кереп, биш ел укып, нибарысы өч курсны тәмамладым. Ул елларның

сикәлтәле бусагаларын бәян итеп, мин «Йәгез, бер дога!» исемле роман-хатирәмне яздым. Роман аерым китап булып басылып та чыкты. Кызыксынган укучылар аның белән таныша алалар. Шәп роман, монда инде минем бөтен барлыгым, кырыс язмышымның хас дөреслеге... Шуның өчен ул елларны йөгереп кенә үтәм. Нәкыянең һич көтмәгәндә язмышыма кереп китүен үзегез күрерсез.

Икенче курста укып йөргәндә, 1950 елның 22 мартында, мине кулга алдылар һәм Черек күл төрмәсенә илтеп яптылар. 17 декабрьдә Петропавел пересельный төрмәсеннән язган хатымда болай дигәнмен: «Юлдан беренче хатым. 7 декабрьдә Казаннан киттем. Кая барып урнашу билгеле түгел, шулай да Казахстанда, Караганда тирәсендә калдырырлар кебек. Китте башлар, «әллә көнгә, әллә айга, әллә гомерлеккәме?..»

1954 елның сентябрендә, һич көтмәгәндә, сискәндереп, мине Казанга кайтардылар. Тагын этап, Чиләбе, Свердловск төрмәләре, ниһаять, Черек күл! Туган якның төрмәсе дә сөйкемле күренде миңа. Сентябрь башында кайтып төштем дә 2 ай буена «одиночка»да утырдым. Энем Алмаз ул чакта медицина институтында укый иде. Мин аның белән күрештерүләрен үтендем. 54нче ел! Сәяси тоткыннарның эшләре яңадан карала башлаган чак, телгә «реабилитация» дигән яңа сүзләр килеп керде. Кайтуыма ике атна дигәндә Алмаз белән күрештек. Сүзләрнең төрлесе булгандыр, әмма бер соравым алдагы тормышымда үтә әһәмиятле булып калды, язмышымны яңа якка борып җибәрде.

1948 елда гына оешкан безнең лагерь-каторгадан котылып чыккач та илгә кайтулар юк иде. Лагерьдан соң сине этап белән мәңгелек сөргенгә озаталар иде. Киләчәктә гаилә кору хакында уйлаган мизгелләр булдымы икән? Хәтерләмим.

Черек күл төрмәсенең беренче катындагы «одиночка»да мин Нәкыяне исемә төшердем һәм энем Алмаз белән күрешкәч тә: «Ул кыз кайда? Кияүдәме?» – дип сорадым.

Кияүгә чыкмаган икән, Аллага шөкер! Унынчы классны тәмамлап, медицина институтына имтиханнар биреп караган да үтә алмаган, хәзер Иске Әлмәт мәктәбендә укыта икән...

Ике айдан артык Казан төрмәләрендә ятканнан соң, мине үзем чыгып киткән лагерьга кайтардылар. Анда кайтуым-

ның икенче көнендә үк, 54 нең 22 ноябрендә Нәкыягә хат язып салдым. Ике арада хатлар йөри башлады. Менә аларның берсе.

«6 февраль. 1955 ел.
КАРАГАНДА, ФЕДОРОВКА.

«Сагынасыңмы?» – диләр,
Хисләр өчен,
Бу сүз, дуслар, бик, бик кечкенә.
Мин «сагынам» дисәм,
Бу авазда
Җир тетрәгән тавыш ишетелә...

Нәкыя!

Хатыңны алдым. Озак, бик озак көттем мин синнән хатны. Ниһаять, ниһаять... Менә ул хат. Синең җитди, кечкенә рәсемеңнән зурларча таләпчән, җиткән кыз – бөтенләй ят, таныш түгел кыз карый. Мин, озаклап, синең рәсемеңә карап торам да үткәндәге кечкенә Нәкыяне күз алдына китерергә тырышам. Хатыңны соңарып алдым, чөнки күптән түгел генә яңа урынга күчтем, һәм бу да күптән көтелгән хатны бераз тоткарлады. Рәхмәт сиңа, сеңлем, зур рәхмәт. Син хатыңны русча язсаң да, мин татарча гына җавап бирергә булдым... (Лагерьга хатларны бары тик рус телендә генә язарга рөхсәт итәләр иде...)

Үзем хакында: сау-сәламәтмен, тазалыгым яхшы, биш ел инде төрмәдә булсам да, авыр эш белән интегеп җәфа чигәргә туры килмәде. Инде быел өйдә булырмын дип уйлыйм. Бик күп укыйм. Инглиз телен өйрәнүемне дәвам итәм. «Ялгыз йортта сагыш» исемле 4 пәрдәлек пьеса, «Чык бөртеге» исемле повесть язам.

Минем гомер шулай буталчыклы булды ки, тирә-яктан караганда. Кешеләр миңа гаҗәпләнә торганнардыр. Дөрес, ата-анама зур хәсрәт ясасам да, аларның вакытсыз картаюларына сәбәпче булсам да, үземнең бу авыр юлга төшүемә артык үкенгәнем юк. Бу авыр еллар мине тормышны танырга, аның катлаулы сәхифәләрен укырга өйрәттеләр. Бу авыр еллар миңа кешеләрне аңларга ярдәм иттеләр. Бу авыр еллар мине ата-анамны, туганнарымны, дусларымны бәһаләргә

өйрәттеләр. Бу авыр еллар миннән җитди кеше ясадылар. Кемнәрне генә очратмадым мин бу авыр елларда! Тузанлы заводларда, кысан, тынчу вагоннарда, кечкенә, ярымкараңгы төрмә камераларында кемнәр белән генә бер сынык икмәкне бүлешмәдем мин! Тормыш никадәр кыен булса да, аның саен яшисе килә: тормыш никадәр ямьсез булса, аның саен тормышка гашыйк буласың. Дөрес, авыр көннәрдә дә үзеңчә нindидер ямь табасың, язлар килеп, дала өстендә җылы җилләр уйнаганда, үзеңнең кемлегеңне онытып, ерак офыкка озаклап-озаклап карап торасың... Үткән көннәр хакындагы җылы истәлекләр акрын гына уяналар да кайтасы килә, кайтасы... Сагындым мин, бик сагындым ямьле Зәй, Сарман буйларын! Сеңлем, синең бәхетле булуыңа, яшь булуыңа куанам. Син еракта: әниең, туганнарың белән, син беркайчан да мин яшәгән җирнең сөремле, җыерчыклы йөзен күрмәссең. Сезнең белән мин дә үткән көннәрнең авыр хатирәләрен онытырмын, ял итәрмен... Шуңа күрә минем синнән хатлар аласым килә. Әгәр инде минем хатлар синдә авыр уйлар уятсалар, ачуланма. Тормыш – кырыс, ул кешеләр күңеленнән чакма ташы ясый. Әмма туган ил хакында, синең хакта уйлаганда, миндә иң җылы фикерләр генә уяналар. Син минем өчен әле һаман да кечкенә генә, ябык кына шаян кызчык булып калгансың. Синең инде урта мәктәп бетерүеңә, укытучы булып йөрүеңә мин авырлык белән генә ышанам...

Нәкыя! Эшең бик авыр түгелме? Институтка хәзерләнәсеңме? Укыйсыңмы? Хат яз. Кулыңны җылы кысып: Аяз».

27 февральдәгесендә мин ипләп кенә «һөҗүмгә күчкәнмен» һәм хатымны дус кызы Әминә исеменә юллаганмын...

«27 февраль, 1955 ел.<br>КАРАГАНДА, ФЕДОРОВКА.

Нәкыя! Исәнмесез!

Бу хатымны сиңа Әминә аркылы җибәрәм. Сәбәбе: бу хатымның синең туганнарың кулына төшүен теләмәс идем мин. «Нигә?» – диярсең. Гаҗәпләнмә. Бу хатка булачак җавапны син ялгыз гына хәл итсәң иде. Син бу хаттан минем сиңа яза башлавымның бер максатсыз түгеллеген аңларга тиешсең. Ә ул максатны мин артык нык кадерлим. Һәм ул

хакта Синең генә белүеңне теләр идем. Кереш сүзсез ачыктан-ачык яза алмыйм, чөнки минем хатлар әлегә сине куркытып җибәрмәдеме икән? Һич тә көтмәгәндә мин ерак даладан сиңа дәштем, синнән рөхсәт тә сорап тормастан, сиңа үземнең сагышлы тормышымны сөйли башладым. Ачуланма, сеңлем! Тормышның һәр минуты, һәр сәгате минем өчен кадерле. Әле дә яшьлегемнең иң кадерле елларын мин бер максатсыз җилгә очырдым. Миңа 27 яшь, бу инде уен түгел, бу яшьтә кешеләр тормышның җитди проблемаларын хәл итәләр. Һәрбер үткән минут, үткән көн мине яшьлекнең буталчык хыялларыннан айныта, мин киләчәккә омтылам, яшәргә тырышам. Әле моннан бер ел элек кенә минем илгә кайту мәсьәләсе бик шикле иде. Әмма хәзерге шартлардан чыгып, 55 нче елда мин өйдә булырмын дип уйлыйм. Сиңа булган мөнәсәбәтем минем киләчәк елларга бәйләнешле булганга күрә, мин, иреккә чыкканчы ук, Синең белән өр-яңадан танышырга карар иттем. Мин белгәндә Син әле нечкә аяклы, көләч кенә нәни кызчык идең. Синең хатларың буенча мин Синең җитди кыз булып китүеңне күрдем. Әмма Синең яшәешең, Синең тормышың, фикерләрең, теләкләрең – минем өчен әлегә табышмак. Сүзсез фотоңа көн саен карый-карый, мин ул табышмакны чишәргә азапланам, хыялларымда ул сүзсез рәсемгә җан бирәм...

Сине тудырган, Сине үстергән, тәрбияләгән тирәлек, мәктәп һ.б. минем дә яшьлегемнең бишеге иделәр. Шулай да ул бишектә ала кешеләр дә, кола кешеләр дә үсәләр. Кем син? Бу сорау мине борчый, җанымны бимазалый. Шуңа күрә дә мин бер-бер артлы Сиңа хатлар язам, шуңа күрә дә, мин бер эчке калтырау белән, Синнән хатлар көтәм. Язышырга теләрсеңме Син минем белән – бу тулысынча Синең ихтыярда. Син минем нинди хәлдә икәнлегемне беләсең. Шуңа күрә мин кыюсызлык белән күзләремне күтәреп Сиңа карыйм: гаҗәпләнмә Син минем хатларга, мин нидидер сихри маҗаралар эзләмим, мин кеше эзлим. Мин игътибар эзлим, Нәкыя! Дөрес, Син: «Хат язарга да вакытым юк»,– дип язасың. Яшьлекнең татлы назларыннан Синең дикъкатеңне аерып үземә игътибар сорыйм икән, мине рухи хәерче дип уйлама! Тик яшисе килә, кадерле сеңлем! Яшәүне бер мак-

сатсыз булмый диләр бит? Ә мин нинди максат белән яшим соң?! Балалык, яшьлек хыяллары – искиткеч сәяхәтләр, данлы-шанлы хезмәтләр тормышның реаль кыяларына бәрелеп юкка чыктылар. Аек башта романнар, пьесалар белән ачыктан-ачык бер генә теләк калды. Ул теләк: семья. Буш-буйдак булып ничә еллар каңгырып йөрдем, бу еллар җанны алҗыттылар. Җан тынычлык сорый. Кайдадыр, анда, Идел буенда, челтәрле тәрәзәле йорт, йорт янында гаҗәеп исле төнге фиалкалар, тыныч хезмәт, хатын, бала-чагалар... Хәсрәтле юлда арган кешеләр өчен бу – искиткеч бәхет, яшәү максаты. Күп еллар хатын-кыз назыннан мәхрүм булган ирләр генә семьяның чын кадерен аңлыйлардыр кебек...

Менә болар һәммәсе дә минем Сиңа булган хатларны туганлык рамкаларыннан чыгаралар, менә шуңа күрә дә мин бу хатның башкалар кулына төшүен теләмәс идем. Уйлама, әгәр Син миңа җавап язмасаң да, мин Синең хакта иң яхшы, иң саф фикердә калырмын. Минем күңел катылыкка күнекте: нинди генә җавап бирсәң дә, мине «акылдан язган» дип атасаң да, күз яшьләремне күрмәссең Син!

Урамда яз! Түбәләрдән чарылдап су ага. Бүген ял көне. Көндез «Фанфан-тюльпан» дигән кинофильмны карадым. Көндезге аштан соң мин Сиңа хат язам. Сиңа соңгы хатымны 7 февральдә язган идем. Һәр көн эштән кайту белән почтага йөгерәм... Ә Син, бәлки, бөтенләй язмассың?! Кем белә?

Сәламәтлек яхшы. Бу лагерьда да озак булмабыз диләр. Киткәнгә кадәр берәр хат ала алсам иде...

Кулыңны кайнар кысып: АЯЗ.

8 нче Март – Хатын-кызлар бәйрәме белән котлыйм үзеңне! Якыннарга сәлам.

Әминә! Хөрмәтлем! Иң элек Сезне 8 Март бәйрәме белән котлыйм. Бу хатны Нәкыягә тапшырыгыз. Эчтәлеген башкаларга чыгармагыз. Мин Сезгә ышанам, сеңлем!»

Һәм... Ниһаять! «Исеңдәме, «кайтып өйләнермен» дигән сүзләрне онытмадыңмы? Шул көннәр килеп җитә, Син ничек, ризамы?»

Нәкыянең җавабын алгач, мин тигез җирдә тәгәрәп киттем. «Мин «риза» дисәм, ә син кайткач үзгәрсәң?!» – дип язган иде ул.

Илдә үзгәрешләр башланса да, миллионлаган сәяси тоткыннарның алдагы язмышы билгесез иде. Җиде юл чатында аңгыраеп басып торганда, чәчәк кебек кызның «Риза» дигән сүзе чамасыз зур бәхет иде.

Моны тәкъдир димичә ни дисең?!

55 нең көзендә мин илгә кайттым. 56ның февралендә, зур мәшәкатьләр чигеп, университетның икенче курсында укый башладым. Нәкыяне университетка керергә күндергән идем. 56ның сентябреннән ул – беренче курста, мин өченчедә укый башладык. Бәхетле, гөнаһсыз, сөенечле көннәр! Мин Островский урамында фатирда торам, ул Колхоз базары янында яши. Күрешмәгән көнебез юк, сагынышып очрашабыз да өметләребезне ныгытып аерылышабыз. Мин хикәяләр яза башладым. Пьесалар язам. Укыйм. Театрларга бергә йөрибез.

«Чаян» журналының фельетоннар бүлеге мөдире Шәүкәт Галиев мине эшкә чакыргач, тиз үк ризалаштым. 1957 ел, 2 марттан журналда эшли башладым. 4 мартта Нәкыяне үзебезгә алып кайттым. Якын дусларым Фәрваз Миңнуллин белән Зиннур Гыйззәтуллин, энекәшләр безне пилмән пешереп көтеп торганнар.

Безнең өйләнешү студентлар арасында нәни генә сенсация булды. Бишенче курсның сазаган кызлары беренче курста кияүгә чыккан «дурочка»ны күрер өчен махсус күзәтеп йөргәннәр...

Ике яктан да курсташлар «Туй!» «Туй!» дип өзми-куймый тыкырдата башлагач, өч көн туй иттек. Беренче көнне туйда студентлар булды, икенче көнне «чаянчы»лар, күз күргән агай-энене дәштек. Өченче көнгә урыс-улак, күршетирә калды. Туй үзе дә гаҗәп кызык, шау-шулы булды, аның хикмәтләрен дус-ишләр әле дә легенда итеп сөйләп йөриләр.

Мин өченче курсны тәмамлагач укуымны ташладым. Алты елга сузылган мәктәптә «белем» алгач, марксизм-ленинизм нигезләре миңа бер әкият булып кына калды.

1958 елның 31 августында Искәндәр улыбызны алып кайттык.

Язуымны өзеп торырга туры килде, кульязмамны Нәкыя сорап алды, тиз арада укып чыгып, әйләнеп тә керде: «Мак-

танчыклыгың яшь чагында да бар иде, хәзер дә бетеп җитмәгән икән,– диде.– Укучылар «бу бала 1 нче класста ук Аяз абыйсына гашыйк булган түгелме соң?» дип уйларлар! Бер нәрсәне ачыклап кит! Син яшәгән йортта Мирзаһит абыйның хатыны Нәҗия апа – минем әнкәйнең сеңлесе иде ич! Онытгыңмени? Ярата идем мин апамны. Шуңа күрә барып йөри идем».

Юк, онытмаган идем. Нәкыям мин сикертеп кенә үткән елларны сагынып кына искә төшерде: «Искәндәребезне без Яңа Бистәдәге Күл урамындагы бер фатирга алып кайттык, Йортның бүрәнәләре череп-муртаеп беткән, идән такталары кырык биш градуска авышкан. Бихисап авыр вагоннар сөйрәгән поездлар терәлеп диярлек узалар. Өй дер селкенә иде. Суны ерактан ташыйбыз, өйне мич ягып җылытабыз. Алай да Яңа Бистәдә үткәргән көннәребез иң бәхетле, шатлык, сөенечләр тулган көннәр булып хәтердә саклана. Кунаклар килеп тула. Мин укыйм. Бер кулымда китап, икенчесендә – бала. Әле ярый авылдан әнкәй килеп җитте. Бәхетле чаклар! Баграждан Әхмәткә көн аралаш килеп йөрүләреңне ник язмадың? Яңгыр, кар дип тормый идең, утыз чакрым араны эһ тә итмичә җәяү уза идең! Ә хатларың! Көненә икешәр хат язган чакларың була иде. Хат ташучы Халидә: «Ниләр яза икән ул егетең шул кадәр?» – дип бик гаҗәпләнә иде».

Хатлар димәктән, хатларны сансыз-исәпсез яздым мин. Нәкыягә язган йөзләрчә хатларым архивымда саклана. Переделкинога барып 24 көн торсам, иң кимендә 30 хат яза торган идем.

Искәндәрне багарга килеп җиткән Нәүбаһар әбиебез безнең гаиләгә бәхет, татулык алып килде. Авылча зур тормыш мәктәбе узган, тормышның ачысын-төчесен кат-кат татыган бу изге җан балаларга, безгә бар көчен, ихлас мәхәббәтен багышлап, 31 ел бездә яшәде. 87 яшенә җитеп дөнья куйды.

Бала... Тәҗрибәмнән чыгып әйтәм, чын кеше булсын өчен кеше, һичшиксез, әби-бабай җылысын да татып калырга тиеш. Искәндәрдән соң Мансурны алып кайттык. Олы улыбызга 10 яшь дигәндә, төпчегебез Рәшат туды. Әби балаларны күтәп алды, һәммәсен дә тигез яратты. Балалар да әбиләрен чиксез яраттылар. Вафатыннан соң ак мәрмәр ташын да алар

куйдылар һәм һәрвакыт әбиләре җәсәденә барып зиярат кылып торалар.

Нәкыя авырга узгач та мин малай көттем. Туганчы ук һәрберсенең дә исемнәре бар иде. Нәкыя дә малайлар гына табарга теләде һәм Аллаһы Тәгалә безнең теләкләрне кабул итте.

Малайлар үсте, укыдылар, үз вакытын белеп кенә татар кызларына өйләнделәр. Киленнәребез алмаш-тилмәш онык-нәбәрәләр алып кайттылар. Менә без әби-бабай булып, шактый ишле балаларыбызга ияреп, XXI гасырга керергә җыенабыз. Онык-нәбәрәләребез: Галия, Миләүшә, Зифа, Сәлимҗан, Муса – саф татар балалары. Телләре татарча ачылды. Җирдә ямаулы татарлар гына калса да, безнең балаларыбыз ата-бабалары кемнәр икәнен онытмаслар, дип ышанам.

«Үзем турында язу авыр» дип бер язып чыккан идем инде. Кырык дүрт ел бергә яшәгән, кулга-кул тотынышып гаилә корган хатының турында язу тагын да катлаулырак икән. Мактап кына торсаң – «арттыра» диярләр, кимчелекләрендә казынсаң – «вакчыл» диярләр. Безнең гаилә – үрнәк түгел. Гомумән, үрнәк гаиләләр була алмый дип исәплим мин. Ә болай мин Нәкыямә чиксез рәхмәтлемен! Шактый дуамал, мыжык язучының хатыны булып 44 ел яшәү – үзе бер батырлык ул.

*Аяз Гыйләҗев.*

Нәкыя ханымның өстәмәсе:

Аяз абый лагерьдан кайткач, беренче күрүдә мин аны тамчы да ошатмадым. Тәбәнәк кенә, күзлекле, кырыс кына икән – мин «риза» дип хат язган егет. Минем ризалыгым кемгәдер җиңел акыллылык булып тоелырга да мөмкин. Асылда моның җитди сәбәпләре дә бар иде. Аязның әтисе (Мирсәет җизни дип йөртә идек без аны) затлы, укымышлы кешеләрдән иде. Ә Мөгаттәрә апаны (минем булачак кайнанамны) Кәшер кызлар мәдрәсәсендә укыганда ук «Бәләкәй остазбикә» дип атап йөрткәннәр. Аларга, җизнәйләр яшәгән Урта Багражга мин еш барып йөри идем. Бәйрәм-сәй-

рәмнәрдә дә аларда булам, күзләрен, чикләвек җыеп, атналар буе аларда ятам. Икесенең дә сөйләшкән сүзләре Аяз турында гына: сагыналар, җылыйлар, кызганалар. Аязның хатларын кычкырып укыталар. Аңа зур киләчәк юрыйлар. «Язучы булыр әле, үзен танытыр»,– дип юрыйлар. Бу сүзләр әкерен генә аңыма җыела бардылар. Аяз абыйдан беренче хат килгәндә, мин инде аның тормыш хәлләрен шактый ачык күзаллый идем. Шулар өстенә, җизнәй белән Мөгаттәрә апаны кызгану хисләре тоткын егетне миңа якынайттылар. Аяз абыйның хатлары кайнар өермә булып мине урап алдылар да яңа давыллы хисләр дөньясында яшәтә башладылар. Торабара егетемнең күзлеге дә, тәбәнәк буе да онытылды. Минем янымда әйткән сүзендә нык торучы, эшләгәндә ару-талуны белмәгән, ата-анасына игътибарлы, көчле рухлы, талантлы егет калды. Аны ничек яратмыйсың! Без әкрен-әкрен үзебез корган планнарны тормышка ашыра бардык. Һәм менә 44 ел гомер үтеп тә киткән. Тормышта гел генә баллы яңгыр яумый. Беренче чорда Аязны кагып-сугып рәнҗетеп йөрттеләр. Ул елларда мин аңа ышанычлы дус, терәк булырга тырыштым. Хәзер без балалар-оныклар белән бергә җыелабыз да, гомеребез бушка-заяга узмады, дип сөенешәбез. Олыгайган саен хатыннарның дәрәҗәсе арта икән, Аяз мине элеккедән дә ныграк ярата, дип уйлыйм.

## Авыл… Авылдан «Олы юл»га[1]

*(Очерк)*

Мин – авыл баласы. Без озак еллар шәһәр белән авыл арасын якынайту турында кайнар нотыклар сөйләдек, монда сүз бары бер якка – авылны шәһәргә якынайту турында гына бара иде. Хәзер сүз шәһәрне авылга якынайту турында кузгалды.

Авыл – минем бишегем, тәүге якты сукмагым, бабамнарның гомер буразнасы, уйларымның бәреп чыккан чишмә-

[1] Бу мәкалә өлешчә «Татарстан могҗизасы» җыентыгында басылды. *Кара*: Гыйләҗев А. Шәһәр юллары авылга илтә // Гыйләҗев А. Татарстан могҗизасы.– Казан: Тат. кит. нәшр., 1985.– Б. 300–303.

се, хисләремнең язгы шашкын ташкыны, хатирәләремнең иң мөкатдәсе. Авыл – минем гомер юлының сихри башланышы, тере чыганагы... Олы юлга, тормыш-көрәш юлына мин – Зәйдән, Югары Баграж авылыннан, керәшенстаннан чыгып киткән кеше...

Олы юлга...

Шулай дип яздым да – балачагым, сугыш еллары, сугыштан соңгы авыр чор, шул чорның гүзәл кешеләре, аз сүзле, кырыс ирләр, иреннәре мәңгегә ачылмас кебек кысылган, яулыкларын күзләренә төшереп бәйләгән апа-җиңгәләр күз алдымнан тезелеп узды. Сезне калдырып, Олы юлга чыгып, киттем дип әйтүем, зинһар, рәнҗетү булмасын! Сезнең белән дә мин Олы юлда булганмын, гаҗәеп маҗаралы, истәлекле һәм сөенечле булган ул авыр юллар! Алай да, кырык биштә, сугыш тәмам булган елда, мин сездән аерылдым...

Мәктәп дәреслекләрендәге бер мәсьәлә хәтергә төшә.

«А» станциясеннән поезд юлга чыга. «Б» станциясеннән икенчесе кузгала. Ике поездның да кузгалу вакыты, тизлеге бирелгән. Аларның кайчан һәм нинди ераклыкта очрашуларын табу сорала. Поезд күргән юк, безнең як – кара як, күбрәк шул ерак юллар, ыжгырып барган паровозлар турында уйлап утыргангамы, бу мәсьәләне чишү миңа ифрат авыр була торган иде. Баксаң, аның асылы бик гади булган икән! Чыга поезд, бара, тизлек бирелгән, юллар салынган, диспетчерлар тизлекне билгеләгән, дежурныйлар һәммәсен күздә тоталар, семафорлар бер менә дә бер төшә! Бар да бар!..

Әлбәттә, барачак алар. Әлбәттә, алар очрашачак!

Ә менә син, моңарчы беркем белмәгән, бик аз санлы кешеләр генә ишеткән Югары Баграж дигән авылдан әллә кайларга барып җитмәк булып, әллә нинди бөек эшләр майтармак булып чыгып китәсең. Аякта чабата-оек, җилкәдә биштәрле капчык. Капчыкта – Тукай[1], Такташ[2], бер кыерчык ипи һәм чүлли шешәсенә тутырган сары май. Хәтерлисезме, Әмирхан

---

[1] Габдулла Мөхәммәтгариф улы Тукаев (1886–1913) – күренекле татар язучысы, тәнкыйтьче, публицист, тәрҗемәче.

[2] Мөхәммәтһади Хәйрулла улы Такташев (1901–1931) – татар әдәбияты классигы, шагыйрь, драматург.

Еникинең[1] «Матурлык»[2] дигән бөек хикәясендәге ярлы шәкерт Бәдретдинне?! Майны без белән чеметеп ашый торган ярлы баласын?! Без исә майны нәзек очлы чыра белән ашый торган идек. Безнең заман авыллары да әле шундый иде...

Чыгасың Олы юлга. Тормышка әзерлегең дә юк түгел, сиңа унҗиде яшь, тормышның бал түгеллеген бик яхшы аңлыйсың, авыл кешесенең җаны сиңа ап-ачык, крестьян хезмәтенең бар серен син, «тормыш» дигән китаптан укып, үзең белдең, үзең өйрәндең. Авыл сине кеше итеп озатты. Авыл кешесе синең өчен барыннан да элек ифрат тырыш, намуслы, киң күңелле, гади кеше. Аның бер казанлык умач оны өчен никадәр тир түккәнен син үзең күрдең, сугыш елларының хәтәрлеген бергә кичердең, алар белән җигелеп, бәрәңге ызанында сука тарттың. «Трактор, трактор... Сука бабай ерак тор!» дип җырлый-җырлый, без тәртә арасына үзебез кердек...

Никадәр кыен ашасам да, яшьли буразна арасына тәгәрәп керсәм дә, мин – күңелемдә авыл турында Олы уйлар алып Олы юлга чыккан кеше. Мәңге сүнмәс кайнар мәхәббәт алып...

Аннары, аннары...

Олы юлдан атлар уза,
Безгә кала тузаны.
Алда гомер бардыр барын –
Сагындыра узганы!..

Алтынчы дистәне тутырып килгәндә үзеңне тудырган авыл турында бары тик матур уйлыйсы гына килә!

Аз гына, бер-ике сүз белән генә мактанмыйча да эш барып чыкмый икән, кичерерсез!

Гомерем буе авылга тугрылык сакладым, дисәм дә ялгыш түгел, авыл кешеләрен олыладым, әсәрләремдә эшлексез-ялкауларны, яңа заман мещаннарын шактый тукмасам да, крестьян турында күбрәк яхшы сүз әйтергә тырыштым. Авыл

---

[1] Әмирхан Нигъмәтҗан улы Еникиев (1909–2000) – язучы, журналист, тәрҗемәче. Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1982), Татарстанның халык язучысы (1989).

[2] Ә. Еникинең 1964 елда язылган хикәясе.

кешесенә мөнәсәбәт – минем өчен кешеләр белән аңлашу чарасы булып калды. Авызыннан бәрәңгесе күренмәсә дә авыл хезмәтеннән җирәнгән, җирдән аерылган, туган төягән бөтенләйгә ташлаган, яхшы чактамы, кыен чактамы аңа хыянәт иткән кешеләрдә мин рухи кимлек, ярлылык күрдем. Иленнән аерылган кешеләрне мин берчакта да тулы бәхетле итеп исәпләмәдем! Юк, һәркемнең дә авылда туып, үз төбәгендә үлгәнче яшәвен теләмәдем, шәһәргә күчеп, әллә нинди катлы-катлы чиннар, дәрәҗәләр алып та соңгы чиктә авыл турында кайгыртып була. Авыл мең төрле ярдәмгә мохтаҗ, ярдәмнең төрле һәм бик кирәкле юлларын уйлап табып була.

Олыгайган саен авылга мәхәббәтем сүрелмәде, көчәя барды, ачыкланды, авыл турында, кайта-кайта, бөтен гомерем буе яздым. Очрашуларда якташларыма, кадерле юлдашларыма иң-иң газиз сүзләремне әйтергә ашыктым...

Тормыш итәргә әзерләнгәндә ата-ананың сизгерлек һәм киң күңеллек күрсәтүе никадәр кирәк! Җирдә мәрхәмәтле, шәфкатьле җаннар күпме булса, без һәммәсе өчен дә беренче нәүбәттә изге ата-аналарга бурычлы. Гаилә – иң саф чишмә чыганагы, тормышның иң тәэсирле, мәңге онытылмас якты күзәнәге.

Авыл кешесе гомерендә бер булса да йорт салып керергә тиеш. Бу – авыл кагыйдәсе, какшамас законы. Йорт салып та керәлмасаң, син – төшеп калган адәм, мәхлук, булдыксыз җан. Йорт салыр чагы җитә башлагач, кеше иң әүвәл бурасын кайгырта. Бура артыннан йөргәндә, акрын-акрын такта-токтасын, кадагын, кирпечен, нигез ташын, тәрәзә борысларына имәнен, мич капкачы, юшкәләрне берәмтекләп юнәтә, җыя бара. Йорт салып керер өчен еллар буе әзерләнәләр! Ниһаять, аның үз морҗасыннан төтен чыга башлый, хуҗа кешенең абруе арта, аның хакында: «Ә-ә, ул – уналты нигәле, алты почмаклы йорт салып кергән егет!» – дип сөйли башлыйлар. Әгәр берәү гомерендә ике тапкыр йорт җиткерсә, аның даны буыннан-буынга җитә. «Йорт җиткереп улын башка чыгарды!» – дип мактыйлар аны.

Авыл кешесенең ярты гомере йорт салу мәшәкате белән уза иде... Йорт салу мәшәкате аны картайта, йокысыз калдыра, тамактан яздыра.

Шәһәр агайнесе ансат кына, җитез генә кулына ордер һәм ачкыч тотып, әзер фатирга кереп тә утыра. (Алай ук җиңел булмаса да, авыл кешесе шулайрак уйлый.) Өч бүлмәле аның квартирасы, яки икеле, салкын суы килә, кайнар су гөжләп тора... Газы, ваннасы – бөтенесе үзендә! Аерма бармы? Бар! Шәһәр кешесе алдында авыл агае ким кеше булып кала. Авылдан шәһәргә килгәндә ул яңа бурасы белән мактанырга җыенган иде, шәһәр квартирасына килеп кергәч, аның авызы йомыла. «Менә кая киткән икән эшләр!»

Бу тарихи тигезсезлек гомер-гомердән килгән.

Авыл кешесенең беренче җай чыгу белән койрыкны сыртка салып шәһәргә күчүендә дә бу тигезсезлекнең тәэсире бар. Авылның иң уңган кешесе йорт торгызып керү өчен тир түгеп йөргәндә, авылның иң җебегән, иң булдыксыз Гыйльметдине шәһәргә барып өч бүлмәле фатир алган! Гарьлекме? Нинди генә әле!..

Хәзер бәләкәй генә тыныш ясап алыйк...

Замандаш тәнкыйтьчеләр иҗатыма карата бик игътибарлы булдылар, бер генә әсәрем дә алар күзеннән читтә калмады, рәхмәт аларга! Шулай да бер принципиаль мәсьәлә алар игътибарын җәлеп итә алмады кебек! «Берәү», «Качак», «Өч аршын җир» әсәрләрендәге бергәлеккә алар дикъкать итмәделәр сыман. Бүген минем юл башымдагы әнә шул әсәрләргә кире кайтасым килә. Алар минем йөз аклыгым, йөрәк серләрем иде. Алардан башка бүгенге сүземнең эчтәлеге тулы булмаячак, фикерләрем арзан, үзем җиңел холыклы кеше булып күренәчәкмен. Ихлас дөрес әйткән шагыйрь: «Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын, яшәсәгез, мин дә яшәрмен!»

Авыл, аның ул чактагы көне һәм киләчәге мине нык ук борчыган икән заманында! Җир кешесе бүген нинди булырга тиеш? Таяныр нокталары кайда аның? Таянып ял итә торган талларын кисмәгәннәрме? Тормышның шул заман тудырган катлаулы чәбәләнешләренә аның мөнәсәбәте ничек булса хәерлерәк?

Әсәрләр байтактан язылган, күптән басылган, хәзерге заман укучысының белгәне бардыр, белмәгәне дә ишледер, шул сәбәпле ул әсәрләргә чак кына кайтыш ясап алыйкчы! Язылган елларына игътибар итегез: «Качак» белән «Берәү»

1958–1959 елларда язылган. «Өч аршын җир»не Мәскәүдә укыганда, 1962 елның көзендә язган идем. Нигездә берберсеннән бик нык аерылып торган бу әсәрләрне бер итә торган, берләштерә торган җитди мәсьәлә булмаса, бүген аларны телгә алып торуның кирәге булыр идеме? Әнә шул бергәлек, уртаклыкны тәнкыйтьчеләр абайламый калды шикелле! Өч әсәрдә дә җир кешесенең туган җиренә хыянәте турында сүз бара.

«Качак» – хикәягә шундый кискен, яңгыравыклы-шөбһәле исем дә биргәнмен! Балчыклы авылыннан сыер савучы Тәнзилә исемле кыз үз колхозын ташлап качарга ниятли. Сәбәбе җитди. «Тәнзилә үз фермаларын уйлап алды. Өч ел йөреп, күреп күнегелгән урыннар бөтен ваклыклары, су тамып торган юка такта түшәмнәре, кыйшайган яңаклы ишекләре һәм саламнары бүселеп-бүселеп торган түбәләре белән күңелдә калыктылар».

Шундый күңелсез күренешкә өстәмә буларак, хикәядә арык сыерлар, шул арык маллардан алынган тәүлеклек алты литр сөт телгә алына. Председатель дә юньсез! Тупас. Шәһәрдән кунакка кайткан апасы Гөләндәмне станцага кадәр дә озата бара алмый Тәнзилә, председатель җибәрми... Ә Гөләндәм шәһәрдә калач ашый! Ансатрак яшәп, тәмлерәк ашый...

Нәтиҗә ясап, мин Тәнзиләгә хөкемнең иң усалын чыгарганмын, кызны «качак» дип атаганмын. Аның шушы котсыз авылны, шөкәтсез ферманы ташлап китәргә теләвен гаепкә алганмын... Әгәр барыбыз да ташлап китсәк... Барыбыз да җиңел юлга бассак... Җиркәебезгә, туган төягебезгә хыянәт итсәк, – кем тормышны үзгәртер? Җиргә хуҗа булырга үсеп, табигать авыл кырларына мәхәббәтле йөрәк биргән җаннар да аны ташлап китә башласа, дөнья кай якка үзгәрер?!

Тәнзилә яшәгән елларда актив миграция башланмаган иде әле, аның беренче яралгылары гына да мине шөбһәгә төшергән!..

«Берәү» повестенда кырчы-игенче баласы, туган ягын, кешеләрне аерым бер сизгер мәхәббәт белән ярата ала торган Исхак Батуллин турында сүз бара... Сугыш елларында егет булып җиткән Исхак кырларның ятимлеген, ташландык басуларны күреп әрнеп, кыйналып үсә. Шул кырларга

яңача рух өрер өчен, тергезер өчен, авыл хуҗалыгы институтына барып укый... Җиңел адым булмый егет өчен! Кемнәрдер авыл хуҗалыгына гомерләрен багышларга теләгән яшьләрдән көләләр. Исхак гашыйк булган кыз, аның кайда укуын белүгә, араны кырт өзә. Юридик мәктәпкә урнашып, җылыга ояларга күз тоткан Тазюков, дөньяның эчен-тышын аңлатып, егеткә болай ди: «Ни пычагыма сиңа ул сельхоз?! Колхозда интегеп җенең өзелмәдемени әле синең? Күтәрәм атлар торгызып, корчаңгы сыерлар тазартып туймадыңмыни?!»– дип, егетне авылдан качарга үгетли. Бу – ялгыз бер обыватель авазы гына түгел, бу шул заманның байтаклары күңелендә туган куркынычлы-хәвефле фикер иде. Исхак Батуллин колагы төбендә башкачарак сүзләр-өндәүләр дә яңгырый. Калдау калган, шайтан таягы һәм билчән басып бетергән кыр янәшәсендә Имәнле урам очында яшәп яткан яралы партизан Нурулла башкача фикер йөртә: «Төнлә уянам да тыңлап ятам. Әгәренки тәмуг дигән нәрсә булса, аның җиле дә шулай шаулыйдыр, дип уйлыйм. Коточкыч бит!.. Җиргә ятып җылыйсыларым килә... Күз бит, күз! Кыр тулы чүмәлә, кибән, ындыр тулы эскерт, ишегаллары тулы көшел, келәтләр тулы тау-тау икмәк була торган иде. Көз җитә башласа, тәрәзәмне япмый идем мин... Һай, бу басулар! Кыр янында яшисем килеп, шушы Имәнле очыннан күчмәдем мин... Һай, бу кырлар! Аларны адәм төсенә керткәнче чиең чыгар әле... Һай, бу кырларның туфраклары... Шундый бер чакта, йөрәксенеп, агроном булырга йөрисең икән, молодецтан башка сүз юк сиңа. Вәт. Их, егәрләрем булса, мин... кыр тутырып бодай чәчәр идем. Офыктан офыкка бодай кыры булсын иде...»

Без бер тапкыр иген кырларының төп хуҗаларыннан аерылып калганын күрдек инде. Кырык бердә аларны фронт юлларына озатып калдык... Кыр ятим калганда ниләр буласын да белдек... Исхак – шул буын вәкиле. Шулай да ул авылына, туган кырларына, дүрт күз белән аны көтеп торган сыңар күзле Нуруллага хыянәт итә, кача, Казанда, министрлыкта эшкә урнашып кала...

Бәхетлеме Тәнзилә? Юк! Исхак бәхетлеме? Һич! Аерылу газабы, хыянәт газабы аның тынгысыз күңелен өзлексез кимерә... Газап утында яна аның игенче йөрәге!..

Җиргә хыянәтнең формалары төрле-төрле булуы ихтимал. Тарихның ашыгып алга ыргылган мизгелләрендә кыр үз улларын ныклыкта сыный! «Өч аршын җир» повестенда Мирвәли, тере күңелле, ачык җанлы кеше, туган җиренә хыянәт итә... Авылдашлары, тормыш, язмыш аңа менә нинди аяусыз хөкем чыгаралар...

Ил исеменнән, җир исеменнән хөкемне аңа авылдашы, яшьтәше, яшьлек дусты һәм адашы Мирвәли игълан итә. Хыянәтченең авылда калырга ниятен белгәч, ул болай ди:

«Калырга кирәк, дисең инде син... Уйларга кирәк моны! Син миңа үпкәләмә, үткәннәрне искә төшергәнне кайчак үзем дә яратмыйм. Шулай да әйтик, авыл халкы җәбер-җәфаны байтак күрде! Ул сугыштан соңгы интеккәннәрне күрсәң син! Хезмәт көненә берни бирмиләр иде диярлек. Налоглар, заемнар белән җәфаладылар. Еллар буе берни бирмәделәр, еллар буе барын бездән сорадылар... Күзебез ачылды, җитәкләп, безне көр тормышка чыгардылар...»

Хыянәтче Мирвәли дә үз сүзен әйтеп калырга тырыша. Тыңлыйк!

– Миңа күп кирәкми инде хәзер... Күрәсең ич, карта-елды. Яшисе яшәлгән дигәндәй, миңа өч аршын җир җитә хәзер!

Партиянең авыл хуҗалыгында борылыш ясап мәгълүм карарлар чыгарган вакытта бара бу әңгәмә, һәм җир хуҗасы хыянәтчегә мондый җавап юллый:

– Өч аршын сорыйсыңмы? Кадерле ул туган җир! Ай, кадерле! Күпме авылдашлар аның өчен башларын безнең гомердә генә салдылар. Берлинда, Будапештта. Каты бәгырьле, димә, минем ул җир өчен чын-чынлап даулашырга хакым бар! Өч аршын җир!..

Күп сорыйсың син, Мирвәли!.. Хәзер менә сорыйсың! Ә нигә качтың син Карачурадан? Әйт әле!

– Кимсеттеләр мине, җәберләделәр,– дип мыгырданды ул.

– Ә безне?.. Еллар буе кара тир түгеп эшләп берни алмаганда безне кимсетмәделәрме? Әрнемәдекме? Тик туган җиребезне каһәрләп мөртәткә әйләнеп качмадык!

Монда да шул ук кискен, аяусыз хөкем: «Чыгып качмадык!»

Өч әсәрдә өч төрле кеше, өч характер, өч төрле тормыш шартларында, төрле елларда яшәгән кешеләр үз идеалларына хыянәт итеп авылдан качалар... Бу әсәрләрдә генә түгел, алардан шактый соңрак язылган башка әсәрләремдә дә ашыгып-ашыгып колхозларын ташлап киткән кайберәүләргә «чирттереп» узганмын...

Ах, ул «бөек күченеш» чоры. 60–70 нче еллар... Ах, ул катлаулы миграция заманы! Плакатлар, ашыгып-ашыгып, кешеләрне авылдан шәһәргә өндиләр! Директив оешмалар, төрле вәгъдәләр биреп, завод-фабрикаларга кеше чакырдылар! Нефтьче җитәкчеләрдән берәү, үтә җитди рәвештә: «Кайчан романыңны бастырасың инде, безгә эшчеләр җитми!» – дип сорады. Романымда мин авыл кешеләрен нефтькә өндәргә генә тиеш булып чыкканмын икән!.. Кирәк иде, беләбез, аңлыйбыз. Тик аңлау бер яклырак булып чыкты: авыл һич сакмас кое кебек тоелды күпләргә! Чумыр да чумыр, алган саен арта тора! Мин әсәрләремнең берсендә «озакламас, без шәһәрдән авылларга кеше өнди башларбыз» дип язып узганмын... Һәм шул ук «Качак» хикәясендә мәгънәле генә бер эпизод та бар. Тәнзиләләр «тәҗрибә уртаклашырга» күрше бай колхозга баралар. Фермалары шәп боларның, янда гына бакча эчендә уңай терлекчеләр йорты... (Хыялым шуннан арыга уза алмаган!) Бәхетле колхозның бәхетле сыер савучысы Бибинур белән Тәнзилә бер юлдан, янәшә баралар:

«...авылны чыктылар, авыл очындагы бушлыкта җиде-сигез бураны күргәч, Бибинур адымнарын акрынайтты:

– Күрәсезме? Төзиләр! Дүртесе каладан кайтты. Авылдашлар, механизаторлар. Колхозга кабул иттек үзләрен,– диде ул бераз тантаналы төс белән».

Ул вакытта авыл уртасында буш ихаталар юк иде, шәһәрдән авылга кайткан кешеләрне авыл очына – бушлыкка чыгарганмын...

Шулай булган...

Берзаман йортлар бушап, тынып кады, Зәй–Кама буе халкы башта Зәй, Түбән Камага, аннары тоташ чылбыр булып

Чаллыга агылды. Тәрәзәләргә аркылы-торкылы такта кадакланды, ишегалларын кычыткан, алабута басты, эшче куллар җитми башлады.

Ниһаять, авыл турында җитди сүз кузгалды... Көн үзәгендә яңа мәсьәлә калыкты: кадрларны авылга беркетү мәсьәләсе... Башта җиңелрәк карадык, «Ах, яшьләр китәме?.. Күңел ачу урыннары юк, шуңа ташлыйлар авылны!»

Хәзер гаҗәпләнәм, нигә эшне, җаваплы мәсьәләне хәл итүне «ял итү»дән башладык икән?! Без үскәндә дә авыл культура учаклары мактанырлык биналарда түгел иде, әмма тормыш анда чын мәгънәсендә кайнап тора иде!.. Шулай итеп авылга беренче үзгәреш дулкыны килеп кагылды: ярышып-ярышып, кем әрмәннәргә биш бәя биреп, кем урыннардагы шабашникларга ялынып-ялварып, клублар, культура сарайлары сала башладылар. Сәхнә артларына гыжылдавык тавышлы пианинолар менеп кукырайды, бильярд алып кайтып куйдылар, баерак совхоз-колхозлар оркестр юнәттеләр. Клуб ишекләре ачык, үсмерләр шарт та шорт бильярд шары суга, кинолар көн саен күрсәтелә, яңа ачылган культура институтыннан авылларга белгечләр – режиссерлар, китапханәчеләр, дирижерлар кайта башлады.

Тик яшьләр авылда калырга ашыкмады, алар, берәмберәм, һаман шәһәр ягына каерылдылар... Яшьләр генә түгел, зурлар да китте: ирләр, китеп, бер ел хәл-әхвәл алды да гаиләсен чакыртып алды. Авылда эшкә ярамаган карчык-корчык, пенсионер ялгызаклар күзгә күренеп артты. Колхозлар мәктәпләргә якынаерга тырыштылар. «Колхоз мәктәптән башлана!» дигән акыллы лозунг шул елларда туды. Авылда тәэминат яхшырды, шәһәрдә очрамаган дефицит әйберләрне авыл кибетләреннән җиңел генә алып була башлады. Авыл хезмәтчәннәренең тормыш шартлары, хезмәт мөмкинлекләре яхшырды, хезмәткә түләү елдан-ел күтәрелде. Колхозчыларны бүләкләделәр, путевкалар биреп ял йортларына, санаторийларга озаттылар, теләгәннәр чит илләргә сәяхәткә барып кайттылар.

Яңадан-яңа машиналар кайта торды, ил авылдан бернәрсә дә кызганмый башлады... Тик яшьләр һаман авылда калмады... Социологлар төн йокыларын качырып баш ват-

тылар. Санадылар, исәпләп чыгардылар, нәтиҗә ясадылар... Нәтиҗәләр әлегә шатланырлык түгел иде.

Монда бер мөһим моментны чак кына искә алып бетермәдек шикелле! Психологик моментны. Авыл хуҗалыгының артталыгы, сугыш елларындагы һәм сугыштан соңгы чорда булып узган читен хәлләрне тиз генә онытып та булмас... Хак, дөрес, героик еллар иде алар, мактауга лаек тиңдәшсез көч түгелгән еллар!.. Ләкин ул еллардан авыр истәлек булып, ямьсез сөземтә дә калды. «Үзем кыен ашадым, түздем, балам күрмәсен, мин кичергәнне татымасын — авылдан читтәрәк булсын!» дигән уйны ата-аналар балаларга тукымадымы?!

Янәшәдә генә яңа калалар үсеп чыкты, биек-биек йортлар калыкты, ул йортларда каттан катка лифтлар сызгырып йөрде, краннарны боруга, чәчрәп, я салкын, я кайнар су килеп торды. (Бер тапкыр кер юар өчен күпме җылы су кирәклеген авыл апасыннан сорап бел!)

Иң ышанычлы, иң тугры авыл фидакярлары да икеләнде. Әйе, авылда зур үзгәрешләр бара. Әйе, тормыш күзгә күренеп яхшыра. Әйе, клублар салына, кибетләр бай... Шулай да шәһәрдә тормыш уңайлырак. Сменалы эш, әзер квартирага киерелеп кереп утырасың, юллар төзек, мәктәпләр якын, телефон кергән... һәм авыл агае, җилкәсен кашып, шәһәр юлларына ешрак күз сала башлый.

Авыл... Бүгенгесе ничек аның? Иртәгәсе нинди булыр?! Бүгенге тырыш кешеләр урынына иртәгә кемнәр кыр түренә узар?!

Бу турыда уйлау — безнең уртак эшебез. Халык күңелендә калган психологик юшкынны юып, кырып төшерү дә безнең бурыч.

Ашыгыч чаралар күрергә, күп итеп торак йортлар сала башларга кирәк. Ә юллар... Алары көтеп тә торыр! Ата-бабалар йөргән, балалары да йөрер. Юл төзергә үк байлык та, чама да юк әлегә, дип уйласак та...

Менә алда конкрет бурыч. Күз алдында авыллар бетеп бара, таркала. Әгәр болай барса, эшләргә кеше бөтенләй калмый... «Йорттан башларга кирәк эшне, торактан!» дип ялгышалар. Иң әүвәл юллар уздырырга, юллар... Халыкның теңкәсенә тигән нәрсә — юллар. Тормыш яхшырсын дисең

икән – юлларың төзек, каралган булырга тиеш!.. Юллар кечкенә генә авылларны да шәһәрләр, ил белән тоташтыра. Авыл кешесенең офыгын киңәйтә, аның үз-үзенә ышанычын арттыра. Авыл кешеләренең икеләнүләренә чик куярга бик вакыт!.. Җирдән аерылмаган ич аларның җаннары... Күр инде, шул ук авыл кешеләре шәһәргә күчәләр дә, ашыгып-ашыгып, җир, бакча өчен участок эзли башлыйлар... Ял көннәрендә җилкәләрен турайтмыйча түтәл арасында казыналар, сыныйлар, тәҗрибә уздыралар, үстерәләр...

Һәркемнең күңелендә җиргә мәхәббәт ята. Ул буыннан-буынга күчеп килә. Икеләнүчеләрнең канында да ул мәхәббәт бар! Кемдәдер ул хис йокымсырап ята торгандыр, дөнья мазасы белән тупаслангандыр, уятырга кирәк аны, заманга, тормышка яраклаштырырга кирәк!.. Юлсыз авылны якты көнгә, киңлеккә чыгарып булмаячак. Урамнарны тигезләргә, асфальт җәяргә. Ишегалларының да бер өлешен асфальт белән капларга!.. Кибетләргә затлы киемнәр, хатын-кызларга биек үкчәле туфлиләр кайтарып тутырдык. Авыл урамына киеп тә чыга алмагач ни пычагыма ул затлы кием-салым?! Сыер савучы эштән кайтсын, юынып, душ алып, киемнәрен алыштырсын һәм текә-текә басып кына зиннәтле клубка барып, Казан артистларының концертын карап кайтсын... Кайткан чакта урамнар ялт итеп, көлеп-балкып торсын. Аның тар урамнарны киң итеп кайтканын күршеләре күрсен, күрсеннәр – көнләшсеннәр... Һәр авылда, һичшиксез, ял итү урыны – бакча булырга тиеш... Шунда ук буа. Буа өстендә дулкыннар йөгерешеп, күңелне кымырҗытып торсын... Авыл кешесенең күңеле киңлек ягыннан шәһәр кешесенекеннән бер мыскалга да ким түгел! Димәк, кеше шәһәрдә яшәп, тормышта нинди гүзәллек, нинди җиңеллек ала алса, авылда яшәп тә ул шуларны күрсен – шунда гына кадрларны беркетү проблемасы өлешчә хәл ителәчәк... Өлешчә! Әле аның бүген яшәп килгән һәм иртәгә туачак йөзләрчә, меңнәрчә вак-төяк проблемалары булыр...

Юллар салгач, йортларга тотынырга кирәк...

Йортлар. Яңа төр крестьянның тору урыны. Нинди булыр ул? Анда яшәүче кеше кем төсле булыр? Крестьяннан китеп тулысынча эшчегә әйләнерме, әллә урталыкта яңача кеше туармы?

Борынгы заманда корымлы мәгарәдә яшәгәннәр – бер төрле булганнар...

Карындык тәрәзәле, җир идәнле тәбәнәк куышларда яшәгән кешеләр – икенче төрле...

Шыгырдап торган нарат бүрәнәләрдән салынган йортта яшәүченең рухы инде башкача!.. Ул Җирдә, йорты салынган Җирдә нык басып тора... Иртәгәге көн крестьяны кем булыр? Аңа нинди йортлар ошар? Ошармы?!

«Нигә авылдан китәсез?» – дигән сорауны куеп карыйк. Сорау бер,– ә җаваплар төрле-төрле. Берәүләр мәктәп ерак булганга авылдан киткән, «балаларга йөрергә уңайсыз». «Кибет, медпунктның читтә булуы да уңайсыз». Күпчелек «күңелгә ошаган эш юк!» дип җавап бирә. Икенчеләр «мал асрарга җай юк»лыктан зарланалар...

«Күңелгә ошаган эш юк».

Бу, әлбәттә, иң кыен мәсьәлә. Монда әле ныклап уйланасы, җиде кат үлчәп кисәсе бар!..

Хәзер авылда кем яши?! Асылда аларны дүрт төркемгә бүлеп булыр иде. Авыл интеллигенциясе: укытучылар, врачлар, фельдшерлар. Яшьрәк чакта алар мал-туар асрарга теләмиләр. Аларга нәкъ менә шәһәрчә квартиралар, шәһәр шартлары гына кирәк... Олыгайган пенсионерлар да «су ташыйсы, мичкә ягасы булмасын иде... аптека, больница, авыл советы, кибете-мазары да янәшәдә генә булсын иде» дип телиләр... Өченче төркем – күңеле белән дә авылда береккән халык – механизаторлар, сыер савучылар. Совхозның таянычы. Болары әлегә үзләре дә йортлар сала. Аларга «мал-туар асрарлык, яшелчә-җимеш үстерерлек булсын, кош-корт та кирәк, хуҗалыкта ансыз ярамый!» Дүртенче төркемгә мәктәп бетереп, армиядә хезмәт итеп кайткан егет-җилкәнне кертергә була. Болар – яшьләр, яңа өйләнешкәннәр, әлегә сыер-сарык мазасы юк, мич ягасылары да килми, әзергә-бәзер, үз бәхетләренә үзләре чумып, нәкъ каладагыча яшәргә омтылалар...

Иң элек шушы төркемгә ярарга тырышырга кирәк, яшьләрне авылда калдырырга! Һәр гаиләгә аерым йорт сала башласаң, озак та, кыйбат та!.. Анда-монда биш-алты йорт салып кына совхоз-колхозларны квартира кытлыгыннан коткарып булмый. Комплекслы, киң колачлы төзелеш башлап,

тулаем авыллар торгызырга кирәк. Бу һәр яктан уңайлы... Шундый йортларда (кирәкме-юкмы – абзарлы, җылы сарайлы да булсын, мал асрасын, кош-корт тотсын) Җиргә тугры булган, бала-чагаларын, оныкларын да шул тугрылык тойгылары чолганышында тәрбияләргә бурычлы яңа авыл кешеләре!

Кеше кайда гына яшәсә дә, Җир кешесе булып кала. Ул эш-хезмәт аша бәхетен табарга, рәхәт яшәргә тели. Авыл кешесеме ул, район үзәкләрендә яшиме, аның җир белән тыгыз бәйләнешы өзелмәскә тиеш. Бу проблеманың көн тәртибеннән төшкәне юк, тиз генә төшәре дә күренми.

Бүген төзелә торган өр-яңа авыллар берничә елдан ни хәлдә булыр? Урам асфальты көчле-куәтле трактор тәгәрмәче астында изелеп югалмасмы?.. Интегеп, гомер-гомергә үзе йорт салып кергән крестьян, әзер өйнең түренә менеп утыргач, тиеннең кадерен онытмасмы?.. Гомумән, кем ул иртәгәге көн крестьяны?.. Кайберәүләр, иртәгәге көн авыл кешесен күз алдына китергәндә, ул, һичшиксез, үткәндәге юаш, эшчән, җирдә яткан һәр башак өчен яна-көя торган кеше булыр, дип өметләнәләр. Тирәннән ялгышу бу. Иртәгәге крестьян бөтенләе белән башка: яңа шартлар, яңа мөнәсәбәтләр, яңача материаль байлыкта яшәгән, без моңарчы белмәгән кеше булачак. Аның нинди булуы, илгә, җиргә мөнәсәбәте бүгеннән билгеләнә. Димәк, аның тормышын җиңеләйтергә, кул хезмәтен мөмкин кадәр киметергә, аңа заманча иркен тормыш төзергә кирәк. Тик бүгеннән үк шуны да онытмаска кирәк: җир хуҗасына, яңа кешегә таләпчәнлекне киметергә ярамый. Эшнең ансатын, калҗаның майлысын эләктереп калырга теләүчеләр дөнья йөзеннән ансат кына китмәячәк. Крестьян психологиясе – катлаулы категория, иртәгә дә, берсекөнгә дә шулай булып калмасмыни? Яңа кеше яңа шартлар таләп итә. Яңа кеше үзе белән моңарчы барлыгы да беленмәгән характерлар китерә. Әлмәт театрында эшләүче бер иптәшнең гаять моңсуланып, борчылып йөрүен күргәч, мин: «Ни булды?» – дип сорадым... «Фәлән авылда апамның өе янып киткән»,– диде ул. «Корбаннар юк, ут чыкмый тормый, нишлисең инде»,– дип иптәшне юатырга тотынгач, ул миңа менә нәрсә диде: «Анысы шулай! Урамда калмас! Кол-

хоз йорт салу турында кайгыртыр. Мине икенче нәрсә борчый, ут чыккач, авылдашлардан берсе дә янгын сүндерергә килмәгән. Һәркем үзенең алты почмаклы өен, искитмәле каралты-курасын, ак мунчасын, гаражын һәм көтү-көтү терлек-туарын саклап – үз ихатасы янында басып калган...»

Әлбәттә, һәркем яхшы яшәргә тиеш. Халкыбызга мөмкин кадәр мул тормыш төзү – безнең уртак максат. Әмма байлыкның үтә куркыныч ягы да бар: ул сиздермичә, астан-астан гына кешенең җанын суыра. Байлык – чамасын белмәгәндә – аждаһа ул... Үзе өй салып кергән кеше психологиясе белән, дәүләт салып биргән авыл өенә туп-турыдан кереп утырган крестьян – кичәге риясыз колхозчы түгел инде. Димәк, киләчәкне күз алдында тотып, без авыл кешесенең материаль ягын гына түгел, аның мораль киләчәген дә тирәнтен уйлап кайгыртырга тиешбез. Әхлак-мораль нормалары нәкъ без көткәнчә, без өметләнгәнчә булсын иде!

Кеше күңеле хәрәкәттә, аны коры сүз белән генә үзгәртеп тә, үзең теләгән якка ансат кына кертеп җибәреп тә булмый...

Бик нык авыллар бар, аларның төпле, эшлекле, вәгъдәчел, дөрес хуҗалары бар. «Өметсез!» дип аркылы-торкылы сызып ташланган авыллар да бар. Боларның икесендә ике төрле кеше яши. Аларның бүгенгесе генә түгел, иртәгәге көне дә аермалы булачак. Димәк, без буш урында түгел, безгә үрнәк булырлык, өйрәнерлек хуҗалыклар бүген үк бар. Без әнә шул алдынгылар мисалында да үз киләчәгебезне чамалый алабыз.

Авылның кыенлык кичергән чорларында да кырларын ташламаган, хезмәтен кызганмаган авыл халкына гомер буе дан җырларга кирәк... Ләкин бу – мәсьәләнең бер ягы гына шул! Авырлык онытыла, дибез... Шулайдыр, әмма күргән авырлык ниндидер мөһим мизгелләрдә күңелгә килеп иңә дә алдагы көннәрне билгеләгәндә хәлиткеч көчкә әверелә...

Узган ел март аенда җанга якын Югары Баграж авылына кайттым... Югары очтан түбән очка кадәр төштем... Имәнле урамы юк – бер йорт та калмаган... Кәҗә башы урамы да беткән... Урта урамда да анда бер өй, монда – берәү... Багражлылар күбесе Зәйдә, Брежневта, Әлмәттә...

Кемнәр калган соң?.. Бар, анда да, монда да очрап торалар... Ирләрнең күбесе «салмыш»... Эчәләр. Утын кайтарсалар да эчәләр, тегермәннән кайтсалар да җыелалар. Бөтен мөнәсәбәтләргә аракы хуҗа. Авылдашларым үпкәләмәсен! Бер Багражда гына түгел – бөтен авылларда эчәләр! Сарман районы авылларында хатын-кызның шешәгә хирыслыгын әрнеп-сыкрап күпме кеше сөйләде!.. Аракы һәм авыл. Авыр мәсьәлә бу. Күптән түгел генә «механизаторлар арасыннан пенсиягә чыгучылар юк диярлек» дигән шомлы сүзләрне укыдым. Авыл арасындагы хезмәтләре өчен түләү шешә белән генә йөргәнгә, алар, пенсия яшенә җитә алмыйча, «аракы күленә батып» һәлак булалар икән...

Авыл!..

Ул – барыбызның да гомерлек мәхәббәте... Синең бүгенге көнең турында һич тә начар уйлыйсы килми!.. Нинди гүзәл, якты кешеләрең бар синең! Синең тарихың, кабатланмас матурлыгың, моңнарың, эшчән ирләрең, тырышлыклары йөзләренә чыккан уңган хатын-кызларың... Урман-болыннарың, рухыңның сафлыгы, мөнәсәбәтләреңнең эчкерсезлеге... Сөю, мәхәббәт, дуслык, эшкә бирелгәнлек дигән олы мәгънәләрне мин синең улларың аша күңелемә алдым лабаса!.. Ник болай үзгәрдек без?.. Көзге сабаннан соң басу өсләренә кара... кая гына күз салма – орлык тишелеп чыккан. Без калдырган орлык, без әрәм иткән бөртек... Элек без намуслырак идекме әллә?.. Кайсы сукмакларда, елларның кайсы борылышында үзгәрдек соң без?.. Хәзер менә бөтен ил белән, шәһәр белән авыл берләшеп, кулга-кул тотынышып, без синең киләчәгең өчен борчылабыз. Синең шәп яшәвең, синең шәп кеше булуың, синең чын хуҗа булуың безнең барыбыз өчен дә бик кирәк! Син көчле булсаң – ил көчле. Ил көчле булса – без дә гайрәтле...

Авыл юллары шәһәргә килә...
Шәһәр юллары хәзер авылга бара...
Бергә – гомергә!
Мәңгегә!

*1984, август–октябрь*

# Эзләремне эзләдем...[1]

*(Юлъязма)*[2]

«Вакыт ага» дибез, һәм без аны, канга сеңгән гадәт буенча, аккан су кебегрәк күз алдына китерәбез. Асылда, бу – ялгыш караш. Вакыт белән дөнья йөзендәге бер төшенчәне дә, хәтта хыяллардагы бер нәрсәне дә янәшә куеп, чагыштырып карап булмый. Чөнки Вакытның башы һәм азагы юк. Алай да... әйдәгез, Вакытның чиксез олы мәгънәсен күнеккәнчә гадиләштерик тә, уйда, телдә кабул ителгәнчә, «Вакыт ага» дип килешеник. Фикер аңлашылсын өчен, шагыйрьләргә һәм гашыйкларга ияреп, «Вакыт безне ияртеп ага» дип билгелик. Вакыт безне ияртмәсә, аның акканын без каян белер идек?! Асылда, бу да – ялгыш караш. Вакыт мәгълүм бер сызыкка кадәр генә адәм балаларын ияртеп ага! Кеше гомеренең кап уртасында Вакыт бер мәлдә шып туктала! Сизгән кеше аны сизә, сизмәгәннәр – юк. Табигать сизгерлекне җан иясләренә тигез бирми. Мин бу дәһшәтле халәтне кырык яшемдә

---

[1] Әсәр беренче тапкыр 1991 елны «Идел» журналында (№ 10–11) татар һәм рус телләрендә басыла. Алга таба Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Йәгез, бер дога!» (1997, «Аяз Гыйләҗев. Истәлекләр» (2006), «Сайланма әсәрләр» (2013) китапларына кертелә.

[2] Роман-хатирәне («Йәгез, бер дога!» әсәре күздә тотыла.– *М. Х.*) язардан элек, билемне баглап, сагынып, дулкынланып, йокысыз калып, Караганда якларына чыгып киттем. Шунда, Караганда шәһәрендә чакта ук, йөргән юлларымда туган уйларымны куен дәфтәренә терки бардым. Кайбер вакыйгалар, якын дусларымның яшәеше, кылган гамәлләре, романга төшәрдән элек, Актас – Волынка тирәләрендә йөргәндә үк дөньяга килделәр. Мин аларга туктарга, тыелырга ирек бирмәдем. Мөмкин дә түгел иде! Инде роман тәмамланып, әсәрләрнең икесен янәшә куеп карагач, кайбер вакыйгаларның, фикерләрнең, йомгак-нәтиҗәләрнең әз-мәз кабатлануын да шәйләргә була. Ләкин мин аңлы рәвештә текстларны кыскартмадым һәм кирәк дип тә санамыйм. Кайбер фикерләрнең кабатлануы аларның көче турында гына сөйли. Исән чакта, хәтер чүпләнмәгән вакытта романны язып өлгертүемә чиксез куанам. Беренче мәгълүматларга караганда, әсәрне укучыларның бер өлеше, мин теләгәнчә, аңлап кабул итте. Рәхмәт сезгә, мөхтәрәм укучыларым! 18 апрель, 1994. – *А. Гыйләҗев искәрмәсе.*

кичердем. 17 гыйнварга каршы төндә, кичтән, бер кеше булып йокларга ятсам, 17сендә мин бөтенләй бүтән кеше булып уяндым. Төн дәвамында күзәнәкләремнең күпчелеге алмашынган иде. Шул дәвердәге сәер, исемсез тойгыларыма таянып, заманында «Урталыкта» дигән әсәр дә язган идем. Әле ул алмашыну, яңару, яңадан туу сәгатьләремдә ят тойгыларымның барысын аңлап вә аңлатып бетерә алмаганмын: кырык яшем тулган аяусыз сызыктан соң Вакыт, мине мәҗбүри ияртеп, кирегә ага башлаган икән! Аның бу серле хасиятен алтмыш яшем тулгач кына ачыклый, нигезли алдым кебек...

Яшь чагында, гомернең гамьсез беренче яртысында, Вакытны үткәрә алмыйча изаланасың. Вакытның каты кануннары, үз җае, ныклы тәртибе бар, ә син аны тизләтергә, күзгә күренмәгән кануннарга буйсынмаска телисең. Яшьлек үз яшәешеннән беркайчан да канәгать түгел, анда, еракта, серле тоелган офыклар артында, сине бәхет вә сәгадәт, татлы җәннәт көтеп зарыгадыр кебек. Кичне җиткерә алмыйсың, таңнарны чыдамсыз көтеп аласың. Үтә зарыгып язга, җәйгә чыгасың, көннәрне ашыктырып, кабаланып көзгә, кышка керәсең. Безнең бабайларның һәр сүзендә, һәр ымишарәсендә шигъри бер тирән мәгънә ята. «Яз»га, «җәй»гә чыкканнар алар, «көз»гә, «кыш»ка кергәннәр. «Көз», «кыш» Вакытның мәшәкатьле, авыр мизгелләренә керү булса, «яз», «җәй» әнә шул авырлыктан, кышкы бимазалардан чыгу, котылу булып расланган. Гомернең тәүге яртысы аның язы, җәе булып, икенчесе, сүрән яктылык белән өретелгән күләме, көз вә кыш түгелмени?!

Әнә шул күзгә күренмәгән, ләкин барлыгына ышанырга туры килгән серле сызыкны атлап чыгуга, Вакыт искән җилдәй ашыга башлый. Гомернең икенче яртысында көннәргә күз иярми башлый, атна-айларның алышынганын сизмичә дә каласың. Гомернең икенче яртысы ни өчен тиз үтә, дигәндә, җавап бер: син, Вакыт елгасы кануннарына буйсынып, кирегә агасың... Кирегә, бер тапкыр үтеп киткән Вакытыңа таба барасың. Дөнья йөзендәге вакыйгаларга, ыгы-зыгыларга инде син битараф каласың, кешелекнең бәрелешләренә, хәрәкәтенә син үзгәреш кертә алмыйсың, каның суына башлый, ми күзәнәкләре ялкаулана, колак сагая, күз томан белән

каплана. Гомеребезнең икенче яртысында очраткан, танышкан адәмнәрне без тиз онытабыз, укыган китаплар онытыла, күргән шәп киноларның тәэсире дә озакка бармый, теләсәктеләмәсәк тә, без, көчле Вакыт кануннарына буйсынып, бүгенге белән түгел, үткән гомер белән яши башлыйбыз. О, ул якта калган гомер нурлы булып күңелгә сеңгән, кичерешләр бәгырь сандыгына онытылмаска бикләнгән... Халык җырын хәтерлисезме?

Олы юлдан атлар уза,
Безгә кала тузаны.
Алда гомер бардыр барын –
Сагындыра узганы.

Татар җыры – безнең милли хәзинәбез, фәлсәфәбез; җырларыбызга бетмәс-төкәнмәс моң да, бөек фәлсәфә дә яшерелгән. Әйе, олы юллардан шәп юргалар чабып үткән! Әйе, шәп юргалар җигелгән канатлы фәйтуннарга әүкатле[1], текә кешеләр утырган... Безгә Олы юлның әче, кайнар тузаны гына сибелеп калган... Алай да без шул мизгелләрне, күңел хөр чакларны өзелеп сагынабыз... Татарга уйларга, белем алырга, югары үрләргә һич мөмкинлек калмаган озын-озак дәверләрдә дә ул үз барлыгын, яшәешен, өмет-өметсезлеген җырга салган, хыялларының иң мөкатдәсен җырга күчергән. Җырлар – тарихның иң буйсынмас, беркемгә баш бирмәс горур илчеләре алар. Әле безнең үз җырларыбызга чынлап торып игътибар иткәнебез юк. Яшьлек җырларының ихлас тирәнлеген әнә шул Вакыт сызыгының аргы ярына чыккач кына аңлыйсың. Укый-яза белмәгән Чыңгыз хан[2] боерыкларын шигырьгә, җырга салып бирә торган булган. Озын юллар үтәргә тиешле юлчабарлар җырга салган боерыкны бозмаганнар да, оныта да алмаганнар...

Кабатлап әйтәм: килә бер заман, балачак, үсмерчакның татлы еллары хәтергә яңадан иңә, дөнья мәшәкатьләре арасында тәмам онытылып бетә язган әти-әниләр, әби-бабайлар

---

[1] Әүкатле – бай, ризыклы, маллы.

[2] Темучин, Темуҗин (якынча 1155 яки 1162–1227), Монгол империясенә нигез салучы һәм аның беренче ханы; монголларның Кытай, Урта Азия, Кавказ һәм Көнчыгыш Европага яулап алу походларын оештырган полководец.

күңелгә әйләнеп кайта, төшкә дә елларның әллә кайда ерак калганнары ешрак керә, гомердә булмаганны, төшләреңне уртак итәсе, сөйлисе килеп тел кычыта. Син, Вакыт елгасы ихтыярына буйсынып, кирегә агасың, үткәннәргә. Сугыш беткәнгә кырык биш ел үткәндә, бик күпләр сугышчан юлдашларын эзләргә тотыналар... Онык-нәбәрәләр үзләренең хәбәрсез югалган бабаларын, әтиләрен юксынып аваз салалар. Монда тумаган, Сабан туйларына да кайтмаган, илнең җәһәннәм базларына китеп олаккан илгәзәкләр, авылларын, инешләрен, зиратларын бер күрергә зарыгып, татар җиренә кайтып баш оралар, йөз суларын түгәләр. «Туган төягемә алып кайтып җирләгез!» – дип, соңгы теләкләрен белдерәләр. Күңелләребезнең хуҗасы Тәңре аларга иман иңдергән, гомер юлларының кая таба акканын аңлатып биргән...

Гомеремнең яртысы, дип, мин кырык яшемне билгеләдем. Ходай ни язгандыр, әйтүе кыен, кырык-илле тирәләрендә әле Тәңре белән турыдан-туры мөнәсәбәткә кереп булмый... Якын дусларымнан берәү, соңгы чирек гасырда гел аралашып яшәгән кешем, коммунист, шул явыз тәгълиматка – XX гасырда тарихны бозып, адәм улларының җанын, күңелен гарипләндергән иманга фанатикларча баш биргән кеше, быел җитмешен тутыргач кына кинәт үзгәрде, дөньяга бүтән күз белән карый алу бәхетенә иреште. Ул күп юнәлешләрдә ялгыш яшәде, соңарып булса да уянды, яңарды, Вакытның кирегә акканын тоя башлады. Йокылы-уяулы яткан кадерле мәлләрдә дустымның җаны, тәненнән аерылып, ерак юллардан әйләнеп кайта икән. «Йолдызларга барып җитә җаным», – дип сөйләде ул миңа. Йолдызлар – аның үткәннәре, бала чагы, саф чагы, иманы нурлы чак түгелмени?

Үткәндәге ялгышлар, ихтыярсыз кылган гөнаһлар тезелеп искә төшә. Телисеңме-теләмисеңме, безнең буынга хәзер бер нәрсә ап-ачык: адәм балаларын язмыш әрле-бирле йөртә! Теге яки бу гамәлебезне истә тотып, без: «Тегене эшләдем! Моны үтәдем! Үзем таптым! Үзем җиңдем!» – дип масаерга һәм шапырынырга яратсак та, без барыбыз да бар булган ихтыярыбызны язмыш иркенә тапшырып, шуның кануннарына буйсынып кына яшибез. Вакыт бөеклеге алдында без бик кечкенә, кылган гамәлләребез дә тырнак очы хәтле генә...

Караганда тирәләре, Актас–Волынка, Карабас лагерьлары[1] – яшьлегем сеңеп калган сукмаклар. Бу язмаларымда мин аңлы рәвештә шул якларга кайтып барам. Гомеремнең хәерсез сәгатьләрен, атна-айларын хәтер йомгагы сүтә башлый...

Ничә еллар дәвамында әзерләнеп, күңелне көйләп, әледән-әле шушы төбәккә ыргылып, һаман суйлакланып[2], ерак юлдан өркеп, юк-бар сәбәпләрне бар итеп яшәдем дә, ниһаять, кырык эшемне кырык якка чәчеп ташлап, тәвәккәлләдем – Карагандага барырга чыгам. Плацкарт вагонны Мәскәү–Караганда поездына Казанда тактылар, койрыкка. Кыска ыгы-зыгы, саубуллашулар; кузгалабыз, әби калтырчасы сыман дер-дер тәгәрибез. Мин Карагандага барам! Сөйләшүләрдән колакка чалына – вагонда күпчелеге казанлылар яки Татарстан кешеләре, хәзерендә Караганда әйләнәсендә яшәүчеләр икән. Ләкин минем беркем белән дә аралашасым килми, танышасым, сөйләшәсем, сорашасым, белешәсем килми, болар – башка заман кешеләре, бүтән буын вәкилләре, алар бүтән, аңнары башкача, алар мин барасы Караганданы белмиләр дә булыр, болар – үз ихтыярларыннан, үзләре теләп ата-баба җирләрен язмыш иркенә ташлап киткән кешеләр. Качаклар. Яисә качак балалары. Әллә нинди дәлилләр табып, мең төрле тарихи, җитди сәбәпләрне мисалга китереп аклансалар да, мин Идел-йортны ташлап киткән татарларны акламыйм: гаеплемен – яратып бетермим мин аларны. Боз диңгезе белән янәшә гомер иткән якут, чукчалар ямьле Кырым барын белмиләрме әллә? Беләләр, китмиләр. Әйе, татарны кысканнар, изгәннәр, таптаганнар, куркытканнар, көчләгәннәр, мыскыллаганнар, татар нужасын аңлатыр өчен телдә фигыльләр җитмәс, һәммәсе хак, татарлар илдәге язмышларын каһәрләп, нәсел-нәсәпләре белән төйнәлеп, авылы-авылы белән күчеп киткән, дөньяның дүрт ягына та-

---

[1] Караганда шәһәреннән 5 чакрым ераклыкта урнашкан Актас бистәсе урынында 1946 елда хатын-кызлар һәм ирләр лагерьлары төзелә. Шундагы әсирләр (күбесе японнар, немецлар) Актас кирпеч заводында эшләгән. Алар көче белән бистәдә йортлар, мәктәп һәм клуб төзелгән.

[2] Суйлаклану (*диал.*) – ялкаулану, иренү.

ралган. Ләкин кемдер калган ич! Милләтнең каргалган тарихын иңендә тотып, иң авыр язмыш йөген тартып, милләтнең бер өлеше илдә яшәгән...

Кайда гына юк татар башы! Без лагерьда газап чиккән Актаста да бар икән алар, быел кыш, тамагыма балык сөяге кадалып, шифаханәгә кергәч, башына кәләпүш чәпәсә дә, татарлыгын күптән җуйган бер адәм белән аралашкаладык. Кызы белән кияveннән егылып уңган бу татар. Актаста яшәп ята икән тегеләр, кияү без тоткыннар казый башлаган шахтада күмер чаба. Бер кулы белән – күмер, икенче кулы белән акча көри! Актасны мактарга да сүзен таба безнең агай-эне: кибетләрендә аракының ниндие генә юк икән! Кияү күмер базыннан кайтышлый «сулга» чыгып бер яртыны «кага» да бабасына да берне кыстырып кайта! Аракы җәмгыятьнең муллыгын билгеләүче зур көчкә ия булган совет заманында шахтёр кияүгә дә, Актасны туган йорты иткән татар хатынына да сүз әйтәсе килми, тик аларның Татарстан тумалары икәнен уйлагач, күңел болгана... Урамда бер-бер исерек урыс аунап ята икән, аңа төртеп күрсәтеп, үткән-барганнар: «Әнә Василий Фёдоров ята»,– дип җәлләп сүз каталар, Габдрахман яки Бикмөхәммәт егылып ятса: «Әнә исерек татар ауный!» – дип дөнья сасыталар...

Быелдан калмый Актас каласына барасымны белә идем, кичектерергә һич ярамый иде, алай да «авызы аракыдан аерылмаган кияү»нең адресын алмадым, тәмуг газапларында интектергән Актасны оҗмах дип санаган татар миңа нигә? Кәләпүшле агай да миңа рәнҗемәсен, татар булсак та, без инде төрле кыйтга кешеләре...

Юл! Теке-теке барасы. Барабыз. Вагонның төрле почмагында татарча сөйләшенгән сүзләр ара-тирә колакка элена, телләрдә җөмһүрият, ил язмышы түгел, һаман бер балык башын чәйниләр: кем ничек юллап машина алган да, кем кызын бай кияүгә урнаштырган... Кемне эләктергәннәр дә, кемгә ришвәт сонып төрмәдән котылган... Андый затны мактыйлар, котыла алган икән, ул – каһарман, бүтәннәргә гыйбрәт, өлге. Туган якларыннан чыгып баралар лабаса, юк, берәү дә тәрәзәгә ябырылмый, берәүнең дә күз чокырында аерылу газабы шәйләнми, боларның дөньялары кесәләренә

сыеп бетә, һәрчак үзләре белән йөри. Юк, Ходай шаһит, мин бу татарлар Карагандасына бармыйм, анда минем үз шәһәрем, үз калам, үз танышларым.

Очраклы юлдашларым – татарлардан тиз үк ераклашам, каршымда җәелеп утырган былкын[1], симез хатынның баядан бирле нидер бытырдавын аермачык ишетә башлыйм. Вагондагыларның үзара татарча сөйләшкәләп алуына ачуы кабарганмы юантык хатынның, берөзлексез татарны сүгә.

Юлчы хатын Мари Элдан булып чыкты, Морки районыннан... Колхоз председателе Степанов тукмап күлгә ташлаганнан соң, кайтып лапасларында асылынган Мөзәкир Хәкимовның районДашы! Мин, ул бәхетсез татар баласының фаҗигале үлеменә багышлап, «Урамнар артында яшел болын» дигән роман язып бастырган идем. Мөзәкир яшәгән Чедроял авылыннан, ул төбәктән ник бер хат килсен! Коммунистик идеяләр корбаны Мөзәкирнең күпсанлы туганнары да, әткәсе Фәтри агай да тел яшерделәр, дәшмәделәр. Әллә шушы явыз хатын сыңары усал бәндәләр ул як татарларның авызын тегеп бетерделәрме?

Дәшмим, ә хатын татарларны тетә генә!

Имеш, алар ягында бер совхозда директор булып татар эшли икән. Череп баеган, ди, кысык күз! Волгоградта өчәр бүлмәле ике квартир тота, Кырым, Кара диңгезнең шифалы ярында шәхси дача җиткереп кергән, совхоздагы йорт-җирен әйткән дә юк, борылып чыгармын димә.

...имеш, Казанда татар балалары мәктәпкә гел йөрмиләр икән! Укытучылар таяк тотып, һау-һаулап эзәрлекләп, урамнан аларны мәктәпкә алып кайталар икән.

...имеш, дебил, аңгыра татарлар, мотальщиклар, Мәскәүгә баралар икән дә, белер-белмәс урысчалары белән: «Мая хочет хараша жить!» – дип, кәкре пычакларын чыгаралар икән.

...Бауман урамында урысларны татарлардан атлы милиция саклый икән.

...шул татарва үзенә республика сорап яткан була бит әле. Ни эшләргә җыеналар диген!

...ул татарларның пычраклыгы, шакшылыгы! Әле менә почмакта бер хатын пирожки сатып тора. Ун ел битен юмаган

[1] Былкын (*диал.*) – юан, симез.

диярсең, ей-богу! Халаты өстеннән сабан өстерәп трактор үткән диярсең...

Нәкыя ерак юлга озата төшкән иде, безнең татарча сөйләшкәнне мари марҗасы ишетеп торды, шуңа җенләнәме, гарыкканчы сүгенде былкын, татарны каргап теле арыгач, күтәрелеп миңа карады: «Йә, менә сез ни әйтә аласыз? Татарга дәүләт белән идарә итү хокукын бирергә ярыймы?» – дип сорады. Шакшы телле, пычрак ниятле бу хатын белән сәфәр башыннан телгә килсәң... ике тәүлек эчендә керер тишегеңне эзләп тапмассың!.. Мин, ишетелер-ишетелмәс: «Мин дөнья эшләре белән инде кызыксынмыйм»,– дигән булып авызыма су каптым, һәм шушы җүләр авыз юл буе, шар-шар килеп, татар милләтен пычратып-сүгеп, хәкарәтләп[1], милли мөнәсәбәтләрне хәл итеп барды. Бара-бара аңлашылды, мари хатыны урыста кияүдә икән, педагог, Караганда ягасындагы Шахтинск шәһәрендә яши икән. Минем каршымда татарга пычрак атып кинәнгән педагог үз төбәгендә – мәктәбендә, үз ишләре, теләктәшләре арасында ниләр сөйләмәс?! Татарны атлаган саен каһәрли торган урыс дәреслекләре, урыс китаплары укып авызлыкланган кяфирәләр бер ул гынамы? Меңнәр алар, ун меңнәр...

Тимер юлдагы яман хәлләрне, талау-үтерешләрне көндәлек матбугаттан һәрдаим ишетеп-укып торганга, ялгызым сәфәр чыгарга шүрләбрәк йөри идем, вагонга кергәч тә, һәр күләгә – өрәк, һәр күз карашы атылган ук булып күренде. Бара-бара әзрәк тынычландым, тамбур ишеге ачылган саен бөркелеп кергән Рәсәй исенә дә күнектем сыман, бәдрәфкә су килми икән... Су юк икән, ис мул дигән сүз! Барабыз! Туктыйбыз! Торабыз! Тагын авыр шыгырдап кузгалабыз! Мари хатыны, ниһаять, татарларны читкә куеп, өстәге сәкегә сузылган купшы кызы белән сөйләшә, аңа тирән акыл бирә. Караганда пединститутының икенче курсын тәмамлаган, алдагы көндә әнкәсе кебек үк «шәп» педагог булачак кыз бу сәфәреннән татарларның кемлеген өйрәнеп, мәңге онытмаслык итеп хәтерләп кайта инде! 18нче – иң арттагы койрык вагон, поезд шәбәеп бара башласа, як-якка иләмсез чайкала, «бер җиргә килеп сыланмасак ярар иде» дип, Ходама ялва-

[1] Хәкарәтләү – хурлау, кимсетү, мыскыллау.

рам, котым ботым буйлап үкчәгә үк төшә. Җилгәргеч челтәре өстендәге сыңар борчак кебек сикерәм, бер яктан икенче якка авышам...

1950 елның азагында шушы маршрут белән куганнар икән мине. Әгерже, Сарапул... Нократ, Чулман иделләре. Әле күңел уянмады, җаным җирсеми, кунакка баргандай битараф һәм ялкау хәлдә, үзебез урталай ярып барган тирә-якны салкын гына күзәтәм. Тәрәзә пыяласы тонык, астан өскә мәңгегә юылмаслык тузан касмакланып каткан, көн явымлы, сүрән, болытлар, соры урманнарга тия-тия, бер-берсен изеп, таптап агалар. Рәсәйнең караңгылыгын юри көчәйтер өчен миңа ияреп барамы бу診 кургаш түшәкләр? Әллә пыялаларны заманга, чынбарлыкка төс итеп шундый ямьсезләрен, тоныкларын сайлаганнармы?

Әле сәфәремнең максаты үзем өчен аермачык түгел, җан тартканга буйсынып юлга чыккан мәлем, анда ниләр булыр, ни булып бетәр, әле аларын уйламыйм да кебек, «башны салларга салып» үткәннәргә агып барам, ургылып караңгы төште, каралган борыннарын пычрак ояларыннан сузган лампочкалар яктылык китермәделәр, тирә-якка һәм тынычлыгын җуя барган күңелгә шомлы караңгылык кына өстәделәр... Теке-теке килгән тавыш өстендә озак боргалана торгач, мин дә йокымсырадым һәм сигез трактор гөрләвеннән дерт итеп уяндым да...

Җәелеп, таралып, дәү-дәү сыер имиләрен як-якка салындырган Мари Элның «милли каһарманы» йоклый икән... Алты-җиде баллы Кара диңгез үкерәмени, Каф-тау кыяларыннан кар ташкыны ургылып төшә, җир тетри!.. Әгәр хәләл җефете чамасыз гырласа, Япониядә ирләр хатыннарын аерып җибәрә алалар, законда шулай каралган. Ни теләсәм дә, мин бу читлекне ташлап китә алмыйм, чыдарга туры килә, түзәргә кала. Поезд адымын шәбәйткәндә, Ходага шөкер, гырлау кимегән кебек була, туктаганда – эш харап! Дөнья дер селкенә, куркып калтырый...

Иртән Уралны, Свердловскины үттек... Свердловск төрмәсенең биек-биек читлекләре хәтеремдә... Кайчан исә бу хакта бер язасы булыр әле. Свердловск! Хатирәле очрашулар... Бу шәһәрне урыс журналлары Екатеринбург дип атап

йөртә башладылар. Алда ызгыш-талашлар булыр әле, булмый калмас, исемнәр чатнар көннәр алда әле. Канлы исемнәрне иңнәрендә күтәреп торган шәһәрләр берзаман уянырлар. Илаһым, бу талашлар кан-көрәшләргә генә китермәсеннәр!

Карашым тирә-якка сеңә, әле шулай ашыгып чапканда да ян-яктагы хуҗасызлык, тәртипсезлек, буталыш галәмәтләре күзне кисеп-кисеп ала. Кая карама пычрак сыпкылы юллар, ташландык ихаталар, җимерек күперләр, хәрабәгә әйләнгән кирпеч биналар, тагын әллә ниләр әллә кайларда күгәреп, череп, исраф булып ауный. Урман диярлек урманнар юк, бар булганы – тәбәнәк, тарау, ни Аллага, ни муллага, кәкрешкә америка чаганнары: сынык-санак ботакка беткән күгәргән куаклар. Бер файдасызга җирнең татлы канын суырып утыручы чүп-чар агачларны күргәч, японнар телсез кала икән, дип сөйләгәннәр иде...

«Курганга җитәбез!» – дип, кемнәрдер кыбырсый башлады, шушы як кияве Нур Әхмәдиевнең[1] сөйләгәне исемә төште. «Андамы? Анда үрдәкләр «мине ат та мине ат!» дип, мылтык көпшәсе алдына чиратка басалар. Ә балыклар көймәгә үзләре сикерә, көймәне батырмасалар ярар иде дип, эрерәкләрен кире күлгә тибеп төшерәсең. Кияү анда падишаһ белән бер. Иртәнге чәйгә кунакка дәшәләр – биш тавык, ун үрдәк суялар, көндезге ашауга бүлтерек тәкә чалалар, ә кичке бәлешкә тач май сарыкны багышлыйлар... Бай яклар! Таң туса, өйдән өйгә йөртәләр, җаның ни тели, шуны әзерлиләр. Анда барып төпләнгән татар Татарстанның кар-бураннарына, язгы-көзге пычракларына кире әйләнеп кайтмый инде», – дип таң калып сөйләгән иде. Салып утырган мәл булгандыр, табын уртасына шешә чыгарып бастыргач, татарның теле чишелә, мактанырга яратабыз. Аннары ун-егерме елга бер кайтып күренгән шагыйрь кияүне сыйлау чутмыни ул Курган татарларына?

Томанлы кара тәрәзәдән көннең сытык чыраена карап, Нурның Мюнхгаузен[2] булып шыттырган әкиятләрен уйлап, шикләнеп барам. Кемдер сөйләгән иде, Ташкенттан туган-

---

[1] Нур Гариф улы Әхмәдиев (1946–2021) – язучы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1994).

[2] Эрих Распеның 1781 елда язылган атаклы «Барон Мюнхгаузен маҗаралары» герое.

нары кайткан икән дә, шунда кардәш бер ханым хуҗаларның сөремле, пычрак, карлы-бозлы кысан балконнарына чыгып баскан да: «Юк инде... аяк-кулга богау салсалар да, монда кайтасым юк»,– дигән. И-и, дөнья киң, татарның ниндие, нинди киемгә төренгәне, нинди иманнарга баш биргәне юк хәзерге заманда!

Күл буе камышларыдай бер буйда үсеп утырган каен чаукалыгын үттек. Каеннар тапсыз, тоташ буйдан-буйга ап-ак. Сергей Бондарчук: «Сугыш вә дөнья» кинофильмын төшергәндә[1], тәэссорат көчлерәк булсын өчен, каен урманын акшарлап чыктык»,– дип язган иде. Әллә шул акшарлы каеннар калганмы монда? Татарстанда каеннар карала бара, озак та үтмәс, без «кара каеннар» дип җырлый башларбыз. «Мә, ал мине!» дигән сыман җәелеп, тәбәнәк ак ярлы юаш күлләр җәйрәп ята. Ярсыз күлләр күңелдә кызганыч тойгылар уята, дулкыннары чарпалышып йөрәккә кагылып тормагач, корысын күлләре! Акшарланган сәхнә каеннары бетте дигәндә, чираттагы чаукалыкка барып кердек. Каеннар ап-ак килеш сынган, шөкәтсез урман-хәрабәләр безне шактый озак озата барды. «Калыгыз инде, арыгансыздыр, җитәр!» – дип инәлеп карасам да, юк, баралар да баралар. Конвой солдатлары кебек һич арттан калмыйлар! Күпме ил үттек, бихисап соры чакрымнар артта калды, чәчелгән җирләр, печәнле болыннар юк дәрәҗәсендә. Бер файдасызга, буш ята торган бу иңкүлекләрне имгә китереп, ни булса да файдалы үсемлекләр үстереп булмый микәнни? Мәскәү белән Казан арасы искә төште. Урысның төп биләмәләренә барып кергәч, тәртә буе һәм беләк юанлыгы гына калкына алган нәп-нәзек наратларны, кәкре, гарип каеннарны күргәч, күңел тарихка борылып кайта.

Урыслар – искиткеч сугышчан халык. Сугыш осталыгына урысларны җирле шартлар, мөмкинлекләр ирештергән. Чәчкән игене урысның тамагын туйдырырга җитмәгән.

«В старину, когда на нашем континенте не было ещё картофеля, русская деревня кормилась капустой и репой.

---

[1] «Сугыш вә дөнья» 1965–1967 елларда Л. Н. Толстойның (1828–1910) шул исемдәге романы буенча төшерелгән совет нәфис фильмы, дүрт өлештән торучы киноэпопея. Кинематография тарихында иң югары бюджетлы картина. Режиссёры – Сергей Бондарчук.

Скороспелую, стойкую к холодам репу сеяли древние новгородцы. Вдоль городских стен тянулись репища, участки, на которых росла репа. В неурожайные годы, когда рожь вымерзала, выносливая репа заменяла Господину Великому Новгороду хлеб».

«Среди старинных городов-огородников был и красавец Суздаль. Суздальцы копали грядки в речной долине. На иловитой земле вырастили огромные кусты хрена. Суздальский хрен был сочным и острым, как говорят, «злым». Да, хрен злой... но зато богат витамином С, залечивает цингу. Его фитонциды, убивая бактерии, охраняют человека от болезней».
*(«Неделя» атналык газетасыннан)*

Урыс гаскәре шалкан һәм керән ашап кына гайрәт туплый алмаган, әлбәттә. Пешкән шалканны бездә «усрак ашы» дип атап йөртәләр. Керән ашарга да теш арасына симез ит кыстырырга кирәк. Суздаль, Новгород чиркәү гөмбәзләрен алтынга манар өчен дә «керән-шалканнар»ның гайрәте җитенкерәмәгән, үз җирендә торфтан бүтән казылма байлыгы булмаган, нефть, ташкүмер чыкмаган сугышчан урыс милләте күршеләренең әле көнчыгышына, әле көнбатышына яу чабып, иленең экономикасын ныгыткан, тамагын туйдырырлык рәт тапкан. Татарда «Ил талап түгел, җир тарап тамак туйдырдык» дигән гыйбарә шул заманнардан калган. Менә утыз ел дәвамында тоташтан Мәскәү юлын таптыйм, күпме җирләрне чүпләгән шушы кәрлә урманнарга, файдасыз күксеп яткан шушы сазлыкларга карап йөрәк әрни. Төзелешкә яраклы агач та үсми, утынга кисәрлеге дә юк, чалыш-чолыш кәкрәеп утыралар да, тәртә буе калкынгач, авып, дөнья сасытып яталар... Кая карама – хуҗасызлык, файдасыз яткан камышлы үзәннәр... Шанлы-шәүкәтле башкалабызның борын астында шундый хуҗасызлык яшәгәндә, бу якларга акыллы хуҗалар берәр заман килер микән?!

Уйдык-уйдык, тимерьюлчылар утырткан дөньядагы иң файдасыз агач – америка чаганнары чайкалып утыра. Илнең кайсы юлы белән барсаң да, тимерьюлчылар яраткан шушы чаганнарга тап буласың. Валлаһи, дуңгыз күзе букка төшә! Орлыгын көз-кыш кына түгел, язын да мул тарата торган, күрер күзгә ямьсез, әрсез бу чүп агачлар берзаман

урманнар арасына да барып керер кебек. Дөньяда америка чаганы белән эт эчәгесеннән дә әрсезрәк үсемлек вә агач бармы икән?!

Күземне тәрәзәдән алып вагон эченә карагач имәнеп киттем. Күптән түгел генә телевизордан Шри-Ланкадагы канлы бер вакыйганы күрсәткәннәр иде. «Тамил Илама» сугыш чукмарлары[1] намаз вакытында мәчеткә барып керәләр дә Аллаһы Тәгаләгә йөз тоткан гаепсез диндарларны кырып салалар. Шәһитләрнең акка төрелгән йөзләгән мәетләрен күргәч кан калтыраган идем. Эссе, тынчу, сасы вагонда ак җәймәләргә уралган юлдашларым шуларга охшап китте. Шөкер, иплəп-иплəп, халкыбызга дин кайта, дин-иман, тәртип, гореф-гадәтләр сакчысы булып, милләткә хезмәт итәчәк. Дин – иң көчле коралларның берсе, ләкин дин, җирдәге һәрбер корал кебек үк, явызлык ягына да борыла ала. Җирдәге явызлыклар бик күп очракта дин исеменнән эшләнә. Шундый бәла-казалардан Ходай үзе сакласын. Без христианнар, яһүдиләр белән янәшә яшибез, алда, Аурупадагы кебек, чик баганалары кимегәч, буддистлар, индуслар арасына да җиңел барып йөрербез, татарда бүтән диннәргә тирән хөрмәт хисен бүгеннән тәрбияләргә кирәк. Дин аша ясалган яра – иң авыр яра, чөнки ул һәр очракта тәнгә генә түгел, йөрәккә барып тия.

Йокым өзә-төтә булса да, мин берөзлексез төш күрдем. Төш – аңның кирәге калмаган хатирәләрдән, ыбыр-чыбыр истәлекләрдән, җанны авырайткан тәэсирләрдән арынуы ул. Әгәр төш аша бушанмаса, адәм баласының мие тыгызлыкка чыдый алмас иде, һәркем, билгеле бер чикне узкәч, мие түнеп дөнья куяр иде. Төш – Алланың адәм улларына биргән мәрхәмәте, шәфкате ул, без кирәге калмаган хәтер шлагыннан төш ярдәмендә арынабыз, алдагы яшәү хәрәкәте өчен баш миебездә сау күзәнәкләр әзерли торабыз. Лагерь-

[1] 1972 елда Цейлон вилаяте конституция буенча бәйсез Шри-Ланка җөмһүрияте итеп үзгәртелә. 1983 елда үзәк хакимият белән «Тамил Иламаны азат итүче тигрлар» хәрби хәрәкәте арасында коралды конфликт – гражданнар сугышы башлана. Сугыш хәрәкәтләре туктап-туктап торса да, 2009 елга кадәр дәвам итә, сиксән меңгә якын кешенең гомерен өзә.

дан кайткач, бик озак елларга кадәр төшләремә төрмә кереп интектерде, әле дә үземне торымнан-торымга явыз конвой куган, җәберләнгән кол хәлендә күреп куркып уянам, аңга килә алмыйча, озак вакытлар калтырап ятам.

Нигә мин, юлда килгәндә, озак вакытлар, гел-гел тирә-ягыма йотылып, Нур Әхмәдиев, бүтәннәр сөйләгәннәрне хәтеремә алып, алда мине көткән җир турында өзмәс уйладым икән? Юанырга теләдемме, онытылырга гына тырыштыммы?.. Белмим. Күңелем иләс-миләс булгандыр шикелле...

Таң атканда, без Караганда тирәсенә барып кердек. Сулдан, ниһаять, күңелләрне айкалдырып, нидер әйтергә җыенгандай, нәкъ минем күзгә карап, кояш калыкты. Яңа иртә, яңа көн, кояш та яңа. Инде як-ягымда Караганда җирләре. Тигезлек, мич төбе сыман яссылыкларны үтеп, юаш кына сузылган калкулыклар арасыннан дөбердәп барабыз. Гел машинада яки усал конвой тырнагында җәяү йөреп, лагерьда чакта офык юк кебек иде. Алай да Актастан Волынкага этап булып җәяү барганда, эшкә йөргән мәлләрдә бу як даласының котсыз тигезлеген, бертөрлелеген, ярлылыгын чамалый идем.

Сизәм, кояш мине танып алды, чөнки бу мизгелдә күз чокырымда мең вә миллион тоткыннарның моңы куерган, бу каһәрләнгән изге җирне ул минем өчен махсус яктырта, теләктәш җил, күзләремә күләгә төшмәсен өчен, җиңел болытларны куып тарата. «Күр! Кара! Хәтереңне яңарт! Җыла! Куан!» дигән сыман, көн ачылганнан-ачылды, мин соры касмак корым сыланган, юл буе миңа дошманлык кылып, дөнья чынлыгын яшерергә маташкан тәрәзәгә сендем. Йөрәк сикерә, атлыга, күз карашым вагон тәрәзәсе сыйдырган тар манзарадан әллә ниләр эзли. Җаным үксеп җыларга тотынды, күкрәк вагон калтырчаны уздырып дөпелди. Мине бәхетле һәм бәхетсез иткән бу җирләр! Саумы, Актас! Саумы, таш базлары! Саумы, Фёдоровка, Михайловка! Гаҗәеп моңлы, айлы сихри төне белән мине язучы ясаган Майкудук, саумы! Салкын зыкы суыкларда, ярты төндә, баш очында Җидегән йолдыз чиксез зур сорау билгесе булып янганда, усал этләр өрдереп мине йотып алган Карабас, саумы! Таныйсызмы мине?..

Гаҗәп нәрсә бит ул кешенең табигате! «Үзем җәфа чиккән лагерьларны эзләп табып, күреп кайтам бер!» дип, кайчаннан

әзерләндем, көне килеп җитә дигәндә, күңелдә икеләнү: барыргамы? Җүләрлек түгелме бу? Ни эзлисең син аннан? Ни табармын дип өметләнәсең?.. Икеләнүнең сәбәбе шул булгандыр дип тә уйлыйм, җәһәннәмнән бер котылып чыккач, анда кичергәннәрне тулаем берәүгә дә сөйләмисең, үзеңне көчләп-көчләп, андагы җәфалануларны онытырга тырышасың. Бу теләк шулкадәр көчле була ки, лагерьда җандай дус күргән иптәшләреңне дә күңел дәфтәреңнән вакытлыча сызып ташлыйсың. Ул хатирәләргә кайтасы да, хатирәләрне яңартырлык адәми затлар белән очрашасы да килми. Мин котылып чыккач, күпчелек иптәшләр әле анда, тәмуг базларында калды. Украин егете, иң якын дустым Иван Семёнович Велягурский белән кыска гына ара язышкаладык та... Велягурский лагерьда чакта хатлар язды, котылып чыккач тынды, югалды. Кырым татары Эскандер Даирскийның туган-тумачалары Казанның Киров районында яшиләр дип беләм. Эскандер Липецк шәһәреннән Казанга килеп тә киткән, шылтыраткан, без өйдә булмаганбыз... Ныклап күрешим дисә, җаен таба алмас идемени?! Ике елдан артык бергә ашаган-эчкән Берлин егете Һайнц Бем белән 1955 елның җәендә аерылыштык. Соңгы ике хатын ул миңа Решеты шәһәре янындагы тайгадан, чит ил кешеләре өчен оештырылган лагерьдан язды. «Күп лагерьлардан чит ил кешеләрен монда җыйдылар. Француз, чех, болгар, поляк, фин һәм иранлыларны, азат итеп, илләренә озаттылар. Алар Мәскәүгә кадәр поезд белән үз ирекләрендә барачаклар. Без дә азатлык көтеп ятабыз!» Һайнц та югалды, Германиядән хат язмады...

Адреслар да алышкан идек югыйсә, мин дә эзләмәдем, алар да язмадылар. Таралыштык...

«Барам», – дигәч, язучылар арасыннан бер кеше генә өзеп сорау бирде: «Ни эзлисең син анда барып?» – диде Рафаэль Мостафин[1]. Мин өч кешенең исемен атадым: «Япониядә яшәгән, шунда җиде классны татарча бетергән Абдулла Аликазының язмышын белеп булмасмы. Лагерьда күп яктан кү-

[1] Рафаэль Әхмәт улы Мостафин (1931–2011) – күренекле әдип, тәнкыйтьче. Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге әдәби премиясе (1976), Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе (2006) лауреаты.

земне ачкан урыс Мерзленков Александр Васильевичның, Мукачеводан төрмәгә эләккән Ростислав Иванович Илечконың формуляр-делоларын гына булса да бирмәсләрме... Чынлыкта кемнәр иде икән алар?» – дидем. Рафаэль – күпне өйрәнгән егет, мондый киңәшен бирде: «Син, Караганда КГБсына барып кергәнче, мондагы иптәшләрдән, КГБ хезмәткәрләреннән сора, алар шылтыратып куйсыннар, сиңа ярдәм итүне үтенсеннәр. Югыйсә урамнан килеп кергән кешегә алар лагерь документларын берчакта да күрсәтмәсләр!» – диде. Дустым вә каләмдәшем Алексей Литвин[1], инде байтак еллардан бирле ЧК архивында эшләгән кеше, минем үтенечемне КГБ хезмәткәрләренә җиткергәч, алар, Карагандага шылтыратып, киләсемне хәбәр итеп куйдылар...

Вокзалдан шәһәр үзәгенә автобус белән бардым. Дәүләт куркынычсызлыгы идарәсенә кагылдым. 19 август, якшәмбе көн. Тар гына тәрәзәчектән кизү офицер чак кына эзләнде дә кайтыр билетымны тоттырды, кунакханәнең исемен атады һәм бер телефон бирде. «Кирәк булсак шылтыратырсың»,– диде. «Казахстан» кунакханәсенә урнаштым. Казахча «кунак өе» икән. Матур. Эшне бүлмәдәге чебеннәрне кырудан башладым. Казахтан чебеннәренең җанын кыйдым бер. Ике төн тинтерәгән башны мендәргә салып озак кына ятсам да, йокы алмады, әз-мәз тамак ялгагач, шәһәр белән танышырга чыгып киттем. Ары-бире каранып, ятсынып кына Ленин проспектын урадым. Горняклар сарае түбәсенә менеп тезелгән таш сыннарга карап, озак кына уйландым. Шәһәр казах җирендә утыра. Заманча төссез, иясез, милләтсез һәм шыксыз кала икән Караганда! Казахлык сизелми дә дияр идең, бик нык акшарланган, чамасыз бизәнгән, үз төсен җуярлык дәрәҗәдә ясанган казах хатын-кызлары еш очрый, арада егылып китәрлек чибәрләр дә бар. Күпчелек затлы киемнәрдән, кыяфәтләре байларча тук, текә. Бара-бара тимер юл вокзалына төшеп җиткәнмен. Актас лагереннан безнекеләр йөреп салган иде бу вокзалны! Ишелеп, бүселеп төрле

[1] Алтер (Алексей) Львович Литвин (1931–2023) – тарихчы, Россиядә Гражданнар сугышы тарихы буенча белгеч, тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе (1990, 1999).

тарафтан килеп чыккан пассажирлар беләләр микән моны?.. Вокзал алды мәйданында уймак, кәрт ярдәмендә акча җыючы шарлатаннар мыж, аларны уннарча ачык авыз тамаша итә. Хәерчеләр күп. Урам аша салынган җир асты улакларында да алар күпләп утыра. Берәвесе шакшы куллары белән сәләмәгә төрелгән баласын кочаклаган да казахча җырлый. Акчаны мул сибәләр, көмеш ява гына, мин дә салдым: сәфәрем исән-аман тәмамлансын, өйдәгеләр сау торсын!

Кунакханәгә каршы диярлек, чапырышта[1], Ленинга[2] кызыл гранит яркалардан һәйкәл бастырганнар. Якынрак баргач күрәм: юлбашчының такыр башына ике яклап күгәрчен кунган, эңгер-меңгердә Ленинга мөгез чыккан кебек. Казах та өлешсез калмасын, дигән сыман, Горняк сарае каршысына, урам аша, ике шахтёрга, аннан-моннан таслап, дәү, иләмсез һәйкәл бастырып куйганнар. Шахтёрлар кочаклашкан, милләтләр дуслыгын ныгытучы бу монументтагы икенче шахтёрны теләсә кем дип уйла... Ленин да тупас, шыксыз. Бернард Шоу[3] авызыннан дип, газеталарның берсе мондый сүзне әйттергән иде: «Антикоммунизм – величайшая глупость XX века». Кайбер чыганаклар мондый «акыллы» сүзне Томас Манн[4] әйткән дип баралар. Ай-һай, акыллы һәм тапкыр Бернард Шоу әйтте микән мондый ахмаклыкны? XX гасырдагы сәяси системаларның төбен-тамырын аңлаган, «Майор Барбара»[5] пьесасында корал ясау короле Андершафт исеменнән дөньяның әче хакыйкатен әйтеп калдырган Шоу андый тупас хата җибәрер микән? Муаммар Каддафи[6], Фи-

---

[1] Чапырыш (*диал.*) – кыйгач.

[2] Владимир Ильич Ленин (Ульянов; 1870–1924) – СССРның сәясәт һәм дәүләт эшлеклесе, большевиклар фиркасенә нигез салучы, 1917 елгы Октябрь инкыйлабын оештыручыларның берсе.

[3] Джордж Бернард Шоу (1856–1950) – британ язучысы, драматург, Нобель премиясе лауреаты (1925), җәмәгать эшлеклесе.

[4] Пауль Томас Манн (1875–1955) – немец язучысы, эпик роман язу остасы, Нобель премиясе лауреаты (1929).

[5] Бернард Шоуның 1905 елда язылган иң уңышлы әсәрләренең берсе.

[6] Мөәммәр бине Мөхәммәт Әбү Мәнйар Габдел Сәлам бине Хәмит әл-Каддафи (1942–2011) – Ливиянең сәясәт һәм дәүләт эшлеклесе, Ливия җәмәһириясе башлыгы (1969–2011), полковник.

дель Кастро[1], Саддам Хөсәен[2] кебек канечкеч диктаторлар Ленинның «Дәүләт һәм революция» китабын[3] кулдан төшермиләр икән. Әтәч диктатор Даниэль Ортега[4] ишеләргә дә көчле корал калдырды Ленин. Ленинның теоретик кораллары җитмәгән очракта, Россия, үз гражданнарының авызыннан өзеп, дөньяның бөтен почмакларына корал озата тора. Бушлай, дусларча бүләк итеп озата. Бик күп афәтләр, канлы бәрелешләр Рәсәй коралы ярдәмендә тормышка ашырыла. Ленин тәгълиматын без өзек-өзек кенә, үзебезгә кирәк кадәр генә ятлыйбыз. Берчакта да тирәнгә кереп, аның яман асылын аңларга тырышмыйбыз. Илдә әхлак бозылды, иман тапталды, явызлык өскә чыкты. Караклык, әләк-чәләк, коррупция, ришвәт чәчәк аткан икән, болар һәммәсе дә — Ленин тәгълиматының җимешләре! Ленинның «Яшьләр союзының бурычлары» дигән әсәрен илдә кем генә белми икән? «Укырга, укырга һәм укырга!» дигән чакыру шушы китаптан, һәм бу сүзләр безгә бөтен почмаклардан чекерәеп карап торалар. Ә әсәрнең асылын тәшкил иткән «Мы отвергаем нравственность и мораль, как понятия буржуазные, как инструмент, который был нужен ей для подавления рабочего класса!» дигән дәһшәтле чакыруына безнең күз җитми. Сталинны[5] сүгәбез, каргыйбыз, ул исә үзенең Укытучысының теоретик фикерләрен тормышка ашыручы гына булган...

---

[1] Фидель Алехандро Кастро Рус (1926—2016) — Кубаның дәүләт, сәясәт һәм партия эшлеклесе. 1959—2008 елларда — Куба җитәкчесе.

[2] Саддам Хөсәен Әбдел Мәҗид әт-Тикрити (1937—2006) — Иракның дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе, 1979—2003 елларга чаклы президент, премьер-министр вазифаларын башкара, маршал.

[3] В. И. Ленинның 1917 елның август-сентябрь айларында подпольеда язган фундаменталь хезмәте.

[4] Хосе Даниэль Ортега Сааведра (1945) — Никарагуаның дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе, 1985—1990 елларда һәм 2006 елның ноябрь аеннан башлап бүгенге көнгә кадәр — Никарагуа президенты.

[5] Иосиф Виссарионович Сталин (Джугашвили, 1879—1953) — дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе. 1929—1953 елларда СССР белән идарә итә. Тарихка «канлы диктатор» буларак та кереп калган җитәкче.

Юлда колагымны сасыткан мари хатыны: «Ишеттегезме, Ленинны да агулап үтергәннәр икән»,– диде. Ялгыш кына телемнән ычкынды: «Тумаган булса, шәбрәк тә буласы икән...» – дидем. Хатынны күрсәгез! Күтәрелеп бәрелде, төкерекләрен чәчә, каргана. «Ленин да бетсә, кемгә табынырбыз? Кемнән цитаталар китерербез?» – дип кычкыра. Соңгы чирек гасырда тоталитар режимның иң ышанычлы коллары – укытучылар булды. Алар арасында якты кешеләр аз калды, күпчелек – надан, югарыдан ни әйтсәләр, шуны такылдаучы саесканнарга әйләнде. Әйе, Ленин белән Маяковский[1] – наданнар өчен цитаталар коесы, әз генә иеләсең дә чумырып кына чыгарасың! Берчакта да тормышка ашмаслык зарарлы цитаталар аларда тулып ята. Дөньяның һәр мизгеленә, фикернең һәр бозык адымына Ленин, Маяковскийдан таяныч таба аласың. Шулар ярдәмендә дөнья тарихы бозылды, адәм улларының табигый үсеш законнары актарылып ташланды. XX гасыр – гарип диктаторлар, шизофрениклар заманы, канечкеч власть сөючеләр заманы. А. И. Солженицын «Архипелаг ГУЛАГ» исемле атаклы әсәрендә[2], мәкаләләрендә бу хакыйкатькә мисалларны бик күп китерә. Антонов-Овсеенко «Тиран портреты» дигән мәшһүр китабында[3]: «Сталинга юлны Ленин ачты»,– дип язды. Урыс рәссамы Илья Глазунов[4] «Ленин – величайший злодей XX века» дигән фикерен халыкка җиткерде.

---

[1] Владимир Владимирович Маяковский (1893–1930) – XX гасыр рус әдәбиятының танылган шагыйре.

[2] Александр Исаевич Солженицын (1918–2008) – рус язучысы, драматург, публицист. «Архипелаг ГУЛАГ» – 1918–1956 елларда СССРда барган репрессия турындагы әдәби-тарихи әсәр.

[3] Антон Владимирович Антонов-Овсеенко (1920–1913) – тарихчы, язучы, ГУЛАГ тарихы музее директоры. И. В. Сталин җинаятьләрен фаш итүче «Тиран портреты» китабы Россиядә өч тапкыр басыла (гомуми тиражы – йөз мең данә). Әсәрнең чыганагы булып рәсми документлар, мемуарлар гына түгел, большевиклар арасында тар даирәдә генә сөйләнгән хикәяләр дә тора.

[4] Илья Сергеевич Глазунов (1930–2017) – рәссам, педагог, Россия рәсем сәнгате, скульптура һәм архитектура академиясенә нигез салучы, аның ректоры. СССРның халык рәссамы (1980), Россиянең Дәүләт премиясе лауреаты (1997).

Мөгезле Ленин яныннан кырын-кырын карап, шыпырт кына үтеп киттем. Алла сакласын, җиргә яңа тиран килмәс дип кем әйтә ала? Алда киләчәк һәр тиран, һичшиксез, уң кулын Ленин томнарына куеп сөйләячәк. Фәрештәләр җиргә сирәк иңсә, тираннар, ал байраклар тотып, җәһәннәмнән, Җир үзәгеннән чыга торалар. Шуңа күрә адәм улларының терелләре күккә карап хыялланырга, уйланырга гадәтләнгәннәр. Адәмнәрнең җиргә ерак, серле бер планетадан китерелүләренә хәзер һичкем шикләнмидер дип уйлыйм. Адәмнең беренчел формалары, әлбәттә, космос киңлекләрендә яралган. Шуңа күрә без, хыялланганда, борыныбыз белән җиргә кадалмыйбыз, тезләнеп күккә багабыз, тирән сагыш белән адәм җанының чишмәсе типкән күккә баш орабыз. Ниһаять, безне Җиргә күчергән кодрәт ияләре бер әйләнеп кайтырга тиеш ләбаса! Җир улларыннан хак, гадел җәмгыять төзү барып чыкмады, адәмнәр кулыннан шәфкать, мәрхәмәт китте. Кешелектән аны Маркс–Ленин тәгълиматы[1] тартып алды. Шушы тәгълиматка таянып, Җирдә тираннар туа торды. Аларны авызлыклар көч бүгенге Җир кешеләрендә юк. Без көчле рух иясе Рейганның[2] безнең илне «явызлык империясе» дип атавына үпкәләгән булып кыланабыз, «ай-һай, яла яга!» имеш. Әгәр динле, иманлы, көчле рухлы Рейган, Тэтчерлар[3] булмаса, явыз Брежнев[4] урынына алмашка нәкъ

---

[1] Марксизмда сул радикаль агымнарның берсе. Пролетариатның капиталистик тәртипләргә каршы көрәше һәм коммунистик җәмгыять төзү законнары турындагы иҗтимагый-сәяси һәм фәлсәфи тәгълимат.

[2] Рональд Уилсон Рейган (1911–2004) – Америка дәүләт эшлеклесе, АКШның кырыгынчы президенты (1981–1989), Калифорниянең утыз өченче губернаторы (1967–1975), 1937 елдан 1960 елларга кадәр Голливуд актёры, Америка киноактёрлары гильдиясе президенты (1947–1952, 1959).

[3] Маргарет Һильда Тэтчер (1925–2013) – Бөекбританиянең җитмеш беренче премьер-министры (1979–1990), баронесса (1992). Бөекбританиянең премьер-министр вазифасындагы бердәнбер хатын-кыз. Аны «Тимер леди» дип тә атыйлар.

[4] Брежнев Леонид Ильич (1906–1982) – 18 ел буе совет дәүләт иерархиясендә югары җитәкче постларны биләгән совет дәүләт һәм партия эшлеклесе. 1964–1966 елларда КПСС ҮКның беренче

аның төсле үк бушкуык тиран менеп утырачак иде бит! Рейган, Тэтчерлар, явызлыкның, тираниянең Мәскәү аша бөтен илләргә таралуыннан куркып, кешелекне махау[1] чиреннән арындырырга теләп кенә, дөньяны ленинизмнан саклап калу бурычын үз өсләренә алдылар[2].

Шәһәр белән танышып йөргәндә, шушы авыр уйлар миннән калмадылар. Үзгә географик пояс, вакыт аермасы өч сәгать – йокы, эш, ашау тәртипләре тәүлек эчендә бозылды. 19 августтан 20 августка каршы төндә йокладыммы-юкмы – белмим. Күңел Актаска омтыла! Мондагы вакытка буйсынып, иртәнге сәгать сигездә әз-мәз капкаладым да тимер юл вокзалына төшеп киттем. Көн болытлы, салкын. Озын вә мәгънәсез Совет проспекты буйлап барам. «Советский» исемен йөрткәнгә күңелгә тияме бу урам? Автовокзал да тимер юлныкы белән янәшә икән. Тавыш, ыгы-зыгы, чәбәләнү, күзе тонган сәфәрчеләр, талаш, кагылып, төртелеп китүләр, күзне тырный торган озын-озын чиратлар. Аяк асты юеш, пычрак. Кичәге кыска итәк кигән купшы казах кызлары бүген төренгәннәр, күз-кашлар гына Африка кабиләләренең битлекләрен хәтерләтә. Белешмәләр марҗасыннан юлны сорашам, нидер мыгырдый, колагым сак, ишетмим генә бит! Тук, кызгылт чыраена карап соравымны өченче кат әйтергә кыймадым: йә берәр нәрсә белән алып бәрер, усаллыгы йөзенә чыккан. Вокзал яны мәйданына чыктым, баш очында, багана очларында белешмә такталары эленгән икән. Актас та, Волынка да күренмәде. Диспетчер янына килдем. Мөлаем тавышлы яшь кенә ханым ачыклап бирде: «Актаска 41нче автобус йөри»,– диде. Менә кайда икән ул – иң кырыйдагы бүлемтектә! Барып бастым. Кеше аз, ишле бала-ча-

---

секретаре, 1966–1982 һәм 1977–1982 елларда КПСС ҮК Генераль секретаре, 1960–1964 елларда СССР Югары Советы Президиумы Председателе.

[1] Махау – йогышлы тире авыруы.

[2] Үзенең коммунистик принциплардан чигенмәсен белдереп шөһрәт алган Ленинград химигы Нина Андреева да «үзгәртеп коруны оештыручылар» дип Рональд Рейган белән Маргарет Тэтчерны исәпли икән. Ләкин без бу мәсьәләгә бөтенләй бүтән күзлектән, капма-каршы ноктадан карыйбыз.– *Аяз Гыйләҗев искәрмәсе*.

га, койты киенгән, йончыган адәмнәр дә бар. Хәрбиләр бик күп. Ничәмә-ничә юнәлешкә китәргә торган чиратларның һәммәсендә дә погоннар, кокардалар елтырый. Үгез җигәрлек таза-таза пәһлеваннар вәкарь белән генә, чын хуҗаларча басып торалар. Өтек кенә, төсе уңган автобус мин терәп торган багана турына килеп туктады. Сараньга бара икән. Таныш исем! Актастан – Сараньга, Сараньнан Актаска этаплар йөреп кенә тора иде. Белештем, шушы өтек арба Сараньга Актас аша бара икән. Үзем өчен әкияти тоелган сәфәр язмышына гади генә «Актас», «Сарань» дигән сүзләр катышып юлым ачыклангач, боегып киттем. Актаска бару минем өчен тиңдәшсез олы могҗиза булып тоела иде ич! Ә монда – кер дә утыр, билет бәһасе дә унбиш тиен генә!

Кереп утырдык, дулкынлануымның чиге-чамасы юк, хисләремне гади сүзләр белән генә берчакта да аңлата алмадым, төш күрәм дә кебек, өн дә сыман, күз карашым, каушап, тирә-якны тишә, үтәли күрә, күземә автобуска төялгән адәмнәр түгел – юл, юл читендәге котсыз агачлар гына күренә! Юл! Мин юлда! Кырык елга якын вакыт үткәннән соң, мин Актаска барам! Алып бармыйлар, үзем барам. Актас бар икән, яши икән! Байтак төрмәләр, лагерьлар аша үтсәм дә, Актас, анда күргәннәр, кичергәннәр, андагы иптәшләр, вакыйгалар ныграк истә калган. Йөзләгән исемнәр, кешеләрнең йөз-кыяфәтләре әле дә истә!

Юл, юл, юл! Барабыз! Кемдер керә, кемдер чыга, артка кереп утырган хәрбиләр кымшанмыйлар. Кая баралар диген?.. Шахтёрлар каласы америка чаганына гашыйк икән, ике яктагы куе чаган урманы Хрущёв[1] бабайга һәйкәл булырлык биш катлы шөкәтсез йортларны шактый нык яшергән. Бәлки, мин дә төзешкән 19, 21нче мәхәлләләрне телеп үтеп барабыздыр? «Актас якын гына ул!» – диделәр миңа. Америка чаганнарын шәһәрләрдә күргән саен, күңелемдә бер уй калка. Христиан дине безнең Зәй якларында чиркәүне мул салдырган. Керәшен авылларындагы чиркәүләр – агач-

[1] Никита Сергеевич Хрущёв (1894–1971) – совет дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе, КПСС ҮКның беренче секретаре (1953–1964), СССР Министрлар Советы Рәисе (1958–1964). Н. С. Хрущев идарә иткән еллар тарихка «җепшеклек чоры» дип кереп калган.

тан, урыс авылларында нык итеп таштан салынган. Сәбәп нәрсәдә? Христиан дине татарларда вакытлыча гына, бера-ра вакыт үтәр дә, татарлар тагын исламга кайтыр, дип уй-лаганнармы? Чаган тезгән хуҗалар үзләрен бу җирдә ва-кытлыча гына дип чамалаганнар, ахрысы, чаганнарны җир хуҗалары – казахлар утыртмаганлыгы күренеп тора. Алары исә юкә, каен утырталар иде. Юл, юл, юл! Янәшәмдәге ке-шеләрдән гел сорашып, белешеп барам, алар минем инәләр өстендә утыруымны, «борчалы» кием кигәнемне сизмиләр булыр, гади генә: «Әйтербез, әйтербез!» – дип тынычланды-ралар. Петлицаларына самолётлар ябыштырган гөрс-мәрс аю хәрбиләр төшеп калдылар.

Сулда, асфальттан ерак та түгел, локатор әйләнә! Бу инде очып китәргә килмәгән! Ни генә юктыр бу дала тирәнлекл-рендә! Вагонда шыпырт кына сөйләшенгән сүзләр колагыма еленгән иде: «Монда (шәһәрчек исемен ачык ишетә алма-дым!) уран рудниклары янәшәсендә биологик корал заводы эшли. Ирләре тоташтан пеләш! Яше-картының башы ялты-рап тора!» Сөйләүчеләр таз башларны мәзәк итеп көлеш-теләр, «биологик корал» дигәнгә һич исләре китмәде. Анда да яртысы татар эшлидер әле! Читтән кайтучылар арасында пеләшләр күп күренә башлады, Рәсәйнең агулы, иң зәһәр эш урыннарына безнең агай-эне барып яллана, рудниклар-да чиләнә, төпсез шахталарга барып төшә. Гаҗәп халык! Үз җиренә сыймаса да сыймас икән! Бүтән милләтләр дә үз ара-ларыннан «утлы табаннар»ны аерып чыгаралар, мәсәлән, шәһри Казанда гөрҗи-әрмәннәр байтак кына, тик ник ара-дан берсе кара эштә чиләнсен! Татар бара да җәһәннәм ба-зына дөмегә! Булса да була икән үз кадерен җибәреп йөрүче милләт!..

Күз вә күңел теге елларда ияләнгән даланы эзли. Элек без үткән юллар комлы-балчыклы була торган иде. Үлән-үсем-лекләр сирәк, анда-санда уйдык-уйдык кара әрем үсә дә, тәбәнәк, җирдән ерак китәргә базмаган караганник дигән куаклар була торган иде. Көндезге дүртләрдә җәен ком бу-раны даланы күтәреп китәрдәй булып дулый иде. Җилсез чакта кайларда посып яталардыр, җил дала ярыкларыннан бүре уты – дүңгәләкләрне эзләп таба, аларны куа, тәгәрәтә,

чүмәлә кадәр итеп йомарлый, җил ыжгыра, тузан-туфракны болытларга күтәрә, аяз көннәрне, кояшны томалый. Кыямәт башлана! Ач тоткыннар, күкрәкләрен җилгә куярга тырышып, битләрен җиңнәре белән томалап, сөрлегә-сөрлегә атлыйлар. Ә җил аяусыз, аның ыргымнары тарта, йолка... Җил иркенә бирелеп, сафтан кашык буе гына читкә чыгып кара. Чит-читтән барган ерткыч этләр җилләрдә аерата усалланалар... Комнан сукырайган, җилдән көчсезләнгән дүрт-биш йөз кешелек ачлар колоннасы күз алдыма килеп китте...

Хәзер дала юк, бөтен тараф казылган, чокылган, тишелгән, актарылган, сындырылган, эшерелгән, өелгән... Караганниклар да, дүңгәләкләр дә күренми, офыктан офыкка даланы бөтен киңлегенә җир астыннан гигант сукыр тычканнар казып барган шикелле. Ниндидер предприятиеләр, уңга-сулга каерылган тар юллар, таш коймалар, таш юллар, шахталар, соры таш эскертләре, балчык таулары – терриконнар, аркылы-торкылы чыбык эленгән сансыз-исәпсез кыеш-мыеш баганалар. Утыз-кырык ел эчендә адәм монда теләгәнчә усалланган, көче белән масаеп, җирнең йөзен махау чире йоктырып ермачлаган. Элек, без барында, монда кая карама лагерьлар, кат-кат тимерчыбык киртәләр белән кат-кат чолганган эш, хуҗалык урыннары тезелеп киткән иде, хәзер аларның берсе дә юк, алай да бер җирдә дә ямь, җылылык, аш калмаган. Монда табигатьнең патшасы Homo Sapiens түгел, иблис, убырлар, җиргә үчле җен-пәриләр хуҗалык иткән диярсең. Күзләрем, комарланып, як-якны ашый, әрәмгә үткән елларымны уйлап, җаным сыкрый, дөньяның гаҗәп мәлләрен искә төшереп, бөтен күзәнәкләрем җылый.

Кыямәт көнне Сират күперен кичү өчен күпме вакыт кирәк булачак! Дини чыганаклар ул хакта мәгълүмат бирәме икән? Мин әнә шул кылдан нәзек, кылычтан үткер мәшһүр Сират күперенә кергән адәм хәлендә. Бармы моның очы, азагы күренәме?!

Унда «Дачалар» дип язылган күрсәткеч-такта калды. Тәбәнәк агачлар арасында җилфердәгән керләрне, умарталардан чак кына зуррак йортларны күргәч телсез калдым. Лагерьларны сүтеп дача салганнармы әллә? Агачлар да шул чактан калганмы? Әллә исемсез зиратларны яшерер өчен

корганнармы ул дачаларны? Яңа буынның ваемсыз затлары кадерсез сөякләр, дога көтеп яткан бичара җаннар өстенә тормыш коруларын беләләрме?! Тәнем-җаным, нурым-күгем, бөтен барлыгым-иманым белән як-ягымда сузылып кала барган шушы җиргә сеңдем, тамырларымны бер киңәйтеп, бер тарайтып, кан урынына кайнар, җирле үлчәү берәмлекләренә сыймаган плазма акты. Кеше каны химик составы ягыннан диңгез суы белән бертөрле, хәзерге мәлдә минем тамырларга диңгез генә түгел, океаннар сыеп бетте. Ми тартмасына ут кереп тулды! Ялкын! Көч! Тәрәзәгә йотылуымны белдермәскә тырышам, күземне берәүгә дә күрсәтмим, янәшәмдәге килмешәкләр берни сизми сизүен, җанымдагы уттан автобус ничек дөрләп янып китми?

«Кирпеч заводын ничек табарга?» – дип сорашам, тавышым чыкмый, ирен арамнан иңрәү, сагыш коела. «Искесенме? Яңасынмы?» – дип сорыйлар. «Искесенә, искесенә!» – дип ашыктырам мин. Сарань автобусына тап булуым хәерлегә дә булган әле. Актаска йөрүче автобус иске кирпеч заводына хәтле бармый да икән әле, ә Сарань машинасы нәкъ шуның кырыннан үтә, диләр. Посёлоктан заводка кадәр шактый ара төшәргә кирәк икән әле. Ниһаять, урамнар, йортлар артта калды, сөзәк озын үр төшеп, автобус нәкъ завод каршысына килеп туктады. Икәү төштек, юлдашым – урта яшьләрдәге хатыннан: «Кирпеч заводы шушымы?» – дип сорадым. «Шушы булмыйча», – диде хатын һәм, исе китмичә, генә каядыр кереп югалды.

Ятсынып карап торам: җирне-күкне, тирә-ягымны, заводымны танымыйм. Җир күкрәге ертылып беткән, умырылган, тирән-тирән пычрак чокырлар арасыннан бормалы юллар үтә. Вася Иванов эшләгән котельняның көне-төне пыф-пыф итеп утырган торбасы юк.

Яңарак булсалар да, искерергә өлгергән корылмалар, шөкәтсез биналар, кыек ишекләр, ватык тәрәзәләр, күгәреп, сынып, ярылып беткән шифер түбәләр – барысы да ят. Завод ихатасы тирәли корылган, кош та очып чыга алмаслык чәнечкеле койма да, мин ничәмә-ничә тапкыр үтеп-сүтеп чыккан тимер капка да юк. Кинәт завод ягыннан җил исте. Ис! Таныш ис борынга бәрелде. «Атла!» дип акыручы юк,

таныш искә борынымны турылап, әкрен генә алга атладым. Йомшак кына басам, тыңланам, сагаям, нидер югалтырмын, сизми калырмын, күрмәм, аңламам дип пошынам. Аяк табаннарым, сизәсезме? Минем эзләремне табасызмы?..

Кинәт миңа төбәлеп, мәңгелекне эзләгән күзләремне кисеп, нәкъ каршыма чуар-чабар киенгән тере ташкын убылды... Алар! Йа Раббым! Юлдашларым минем, кадерлеләрем, төрмәдәшләрем! Сез бит бу, сез! 1951 елның уртасында, нәкъ шушы урыннан, көпә-көндез якты кояш читенсенеп кенә далага карап торганда, кирпеч төяргә зонага кергән өр-яңа самосвалны яулап алып, дүрт тоткын качкан иде. Кыска арада дуслашкан Мәскәү студенты Анатолий Кузовкин, авызыннан челемен төшермәгән сүзсез урыс Зонегин, кысык күз кабаклары арасына утлы күмер кыстырган киң күкрәкле, базык, гаять көчле казах егете К. (фамилиясе тел очымда тора, хәтерләмим, исеме дә онытылган), мин бөтенләй белмәгән диярлек, озын буйлы, ачык йөзле, затлы токымлы литвалы ир... Бу машинада якын дустым, әтисе чиркәс, әнисе татар Абдулла Али-казы да качарга тиеш иде. Мин аларның качасын белә идем, Абдулла эшкә безнең заводка түгел, төзелешкә йөри иде, бүген аның карточкасын безнең бригадага күчереп куярга тиешләр иде, план кайдадыр өзелгән, карточкасы булмаганга, аны вахтада тоткарладылар. Аның тимер капкага, каерып алырдай булып, әчтән тотынып карап калганы әле дә күз алдымда.

Казах – җирле егет, юлларны белә, литвалы – оста шофёр; алар, машина хуҗасының касыгына пычак терәп, аны аска алып, өстенә менеп утыралар. Зонегин белән Толя әрҗәдә яталар. Җәй. Һәркайда кирпеч кирәк, машиналар туктаусыз агыла, төялгән машиналар вахта капкасын чыгалар да алдан-арттан шлагбаум уртасында калалар. Очлы лом тоткан солдатлар, әрҗәгә сикереп менеп, кирпечне аралап, йөкне каезлыйлар, җентекләп чокчыналар. Ләкин машиналар күп, тиргә баткан солдатлар кай ара шлагбаумны төшереп тә тормыйлар. Безнең качаклар шуңа исәп тоталар да, капканы чыгуга, машинаны сакчы солдатлар өстенә туптуры юнәлтәләр... Кинәтлектән бер мәлгә югалып калган солдатлар читкә тайпыла, машина ул арада заводтан ерага-

еп та өлгерә... Безнең бригада карьер янында кирпеч блоклар сала иде. Атыш тавышларын ишеткәч, йөрәгем шартлар дәрәҗәгә җитте... Кача алдылармы, юкмы тегеләр? Качкыннарның маршруты мәгълүм, алар, шәһәргә барып кереп, халык арасында эрергә җыеналар. Шәһәргә, шәһәргә! Әмма шәһәргә юл безнең торак зона яныннан гына үтә. Завод ягыннан ишетелгән атыш тавышлары каланчалардагы сакчыларны сагайта, җан-фәрман шашынып чапкан машинаны алар ялгышусыз абайлыйлар һәм ут яудыра башлыйлар. Толя каты яралана, машинаның радиаторы тишелеп, шәһәргә җитәм дигәндә, суы бетеп туктап кала. Исәннәр кайсы кая тая, хәлсез Кузовкинны әрҗәдә калдыралар. «Качыгыз тизрәк!» – дип ялвара ул. Моңарчы ике таза күт астында яткан, касыгына пычак терәлгән шофёр, солдатлар килеп җиткәндә, яхшатлы булып күренер өчен, яралыны, әрҗәдән сөйрәп төшереп, яңаклый башлый. Солдатлар: «Кемнәр качты? Кая киттеләр? Адресларын әйт!» – дип, Толяны кыйнап үтерәләр.

Атна эчендә качкыннарның бүтәннәрен дә тоттылар. Иң соңгысы итеп казах егетен тотып китерделәр. «Кол Изаура» фильмындагы кебек[1], куллары югарыга бәйләнгән, үкчәләре, аяк очлары җиргә тияр-тимәс кенә торган көчле, нурлы казах егетен мәңге онытасым юк. Безгә гыйбрәт итеп асканнар иде аларны...

Кыска бөдрә сакаллы, сызылып кара мыек чыгып килгән ак йөзле, ирләрчә чибәр, яшьли атылган студент Анатолий Кузовкин, якын дустым! Үзара шаяртып, син мине «разночинец» дип атап йөртә идең! Кем искә ала икән сине бүген? Догаларда телгә алып, сагынып, синең җаныңны җылытыр кеше калдымы җир йөзендә? Исәнме син, кыю Зонегин? Батыр литвалы? Бәлки, син «Союдис»та бүген мәйдан тотасыңдыр?..

Җан дусларым, лагерьда чирдән үлеп калган Теодор Августович Цеплитис! Син Робинзон булсаң, синең күләгәң булып йөргән, мине «туганым, чикерткә!» дип үртәргә яраткан Жан Матисович Миезис! Мәңге күңелемнән китмәс, егермедән артык тел белгән профессор Ростислав Иванович

[1] Язучы Бернард Гимарайншның 1875 елда язылган романы буенча төшерелгән Бразилия телесериалы.

Илечко! Мандельштам[1] шигырьләрен укыган, мине Гумилёв[2] әсәрләре белән таныштырган Сергей Сергеевич Козлов-Куманский[3]! Яраслау татары Мигъдәт Динмөхәммәт улы Сәләхетдинов!..

Сез бүген, ирләрчә кочак җәеп, миңа таба ыргыласыз – уртак эзләргә сак кына баса-баса, мин бүген сезне эзләп киләм! Завод бар икән әле, ул тәбәнәкләнгән, як-ягына балчык, лай өелеп, уртада моңаеп калган, аста. Унда – Гофман мичләренең беренче чираты. Авыш ишекләрдән кирпеч чыгарып өйгәннәр, безнең дәвердә кирпечләр ап-ак, Гжель фарфоры сыман чыңлап тора иде, хәзер кирпечләр каралган, димәк, балчыкның сыйфаты үзгәргән, шихта[4] элеккечә түгел... Аяк тавышы чыгармаска тырышып, мич ишекләре каршысыннан сузылган рельслар ягасыннан барам. Бу якның бригадиры озын, юка гәүдәле бандеровчы иде. Аның да исеме сакланмаган, онытылган. Аргы баш мичләренең бригадиры урыс кешесе Пётр Скороходов иде. Гитарачы! Есениннның[5] бөтен шигырьләрен көйгә салып җырлап күрсәткән чыгынкы яңаклы Пётр! Ялны синең белән бер көнне алырга тырышкан, бүлмәдә күләгә сыман шым гына йөргән Гордей карт! «Кардинал» иде синең кушаматың, Гордей дәдәй!.. Сез миңа күпме яхшылык, игелек күрсәттегез! Җылы җаннар! Бүген монда беркем юк, тып-тын, рельслар эргәсендә көл сыман ай тузаны яткан, мондый тузан бүтән бер җирдә дә юк, ул су булып ага, үтеп киткәндә, үкчәләрдән ясалган чокырчыклар тиз үк күмеләләр... Монда газап чиккәннәрнең

---

[1] Осип Эмильевич Мандельштам (1891–1938) – XX гасыр рус әдәбиятының танылган шагыйре.

[2] Николай Степанович Гумилёв (1886–1921) – XX гасыр рус әдәбиятының танылган шагыйре. Контрреволюция тарафдары булуда гаепләнеп кулга алына һәм атып үтерелә.

[3] Сергей Сергеевич Козлов-Куманский (1920–1987) – язучы, журналист. Репрессия корбаны. 1945 елда кулга алына, 1956 елда реабилитацияләнә.

[4] Шихта – металлургия мичләрендә эшкәртү өчен билгеле бер күләмдә алынган материаллар катнашмасы.

[5] Сергей Александрович Есенин (1895–1925) – рус шагыйре, авыл поэзиясе һәм лирикасы вәкиле, иҗатының соңгы чорларында – имажнизм вәкиле.

эзе сакланмасын өчен, Иблис кодрәте белән ясалганмы әллә мондый тузан? Элек тегермәннәрдә бүрәнә җекләренә ак тузан куна иде. Гариф Ахунов[1] аны, «онта» дип, телебезгә кертеп тә җибәрде. Ә бу тузан үлек, котсыз... Җиргә тамган күз яшьләрен дә, кан тамчыларын да йота торган тузан. Беркем очрамавына сөенеп, аяк эзләремне үзем озаграк эшләгән пресс цехына юнәлтәм...

Төнем гасабиланмыйча үтте диярлек, кытайлар эчтеләр-эчтеләр дә сенделәр. Гаҗәп. Төнге бердә телефон шылтырады. Шук кызлар: «Такси чакырдыгызмы?» – дип сорадылар да шаркылдап көлештеләр. Монда, кунакханә тирәсендә, сәер кешеләр күп, ахрысы. Җирле халык, шәһәр егетләре киләләр дә эскәмияләрдә тезелешеп утыралар. Беркая бармыйлар, кузгалмыйлар, берәүне дә көтмиләр сыман. Мин кичке сигездән дә калмыйм, куркам, кереп бикләнәм дә вәссәлам. Кичә алай да гаҗәбрәк бер хәлгә юлыктым, шуңа күрә, кирпеч заводын онытып торып, хәзерге хәлләремне теркәп куясым килә.

Кичке ашны кунакханә ресторанында ашарга җыендым. Беренче мәртәбә керәм! Алтыда ачыла дип килсәм, «җидедә» дип, кире бордылар. Сәгать тулганны көтеп, Үзәк универмаг тирәсен урадым. Якында ул, каршыда гына. Аяк киеменең җайсызын алганмын, үтерә генә! Йөрем күп шул, нишлисең! Борма баскычтан ресторанга менсәм, борын төбендәге бер өстәлдә япа-ялгызы бер адәм утыра. Казах. Утыз-утыз бишләрдә булыр. Хәер, ялгышуым да ихтимал, чын казахның яшен күз күнеккәч кенә әйтеп була. Түшенә ике карбыз кыстырган, артына унар табалы штанга таккан, нык таушалган, көйгән керфекле өшәнгән марҗа каршыма ук килеп, үткер генә бер карап алды да: «Мужчина, вы один?» – дип сорады һәм, җитәкләп дигәндәй, теге ир янына китереп утыртты. Утырабыз, көтәбез, Рәсәй бит, килеп караучы юк.

[1] Гарифҗан Ахунҗан улы Ахунов (1925–2000) – язучы, драматург, публицист һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе. Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1973), Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе (1995). Татарстан Республикасының халык язучысы (1993).

Ярты сәгатьләр көткәч чыдамадым: «Шушы маржа ашатамы безне?» – дип сорадым. Теге бәндә борын тишегеннән генә: «Советлар Союзында кайчан тәртип булганы бар соң?» – дип яман мыгырдап куйды. Дәшмәдем, арыган да идем, үз уйларым үземнән калмаган иде, учыма иягемне терәп, кара бүкәй булып сабыр гына утыра бирдем.

Ниһаять, ризык килде, авызга тәм йөгерде, сүз нидән башлангандыр, казах, кинәт җанланып китеп, тиз-тиз сораша башлады. Каян килдең, нигә, ни бетереп йөрисең һ.б. «Йортлар идарәсендә бухгалтер булып эшләп пенсиягә чыктым, кайчандыр бу тирәдә лагерьда утырган идем, хәзер, яшьлегемне сагынып, эзләремә басып йөрим шунда»,– дидем. Бабасының татар булуын белдерде дә казах, сорамасам да, үзе белән таныштыра башлады. Алма-Атада тора икән, гостиницасы да бүтән, соңгы җир тетрәгәндә ата-анасы йорт-җирсез калганнар да, монда, Карагандага килеп, йорт җиткерергә кирәк-яракны юллап йөри, имеш. Ярый, хәбәрләр алыштык, таныштык, ул, сүзне бүтәнгәрәк каерып, төпченә, сораша башлады: «Казанның яртысы урыслар, татарлар – азчылык, ничек бу хәлгә чыдап торасыз сез?.. Иҗтимагый үзәк ни хәлдә?.. Ниләр планлаштыра?.. Татарлар киләчәктә нишләргә җыеналар?..»

Мин, сарык, ике колагымны әрекмән яфрагыдай шәңкәйтеп, һаман ресторанның идән мунчаласы тәме килгән үтмәс ризыгын күшим, канга сеңгән саклык инстинкты гына телне әйләндерә. «Мин – гади кеше, белемем аз, шуны гына беләм: бездә, Казан татарларында, тар милләтчелек юк, урыслар белән тату яшәү безнең канга сеңгән, сеңдергәннәр. Иҗтимагый хәрәкәттән мин читтә йөрим, картайдым, колак ишетми, күз күрми...» – дип, башны чынлап эшләтергә иренеп, шара-бара тик сөйләп утырам!

Сагаюым шуннан башланды: «Кардәш!» дип кочаклап алган, үз исемен атап, якынаерга тырышкан, теләктәшлек күрсәтеп кызганып уфылдаган казах капылт үзгәрде, торды, кузгалгач борылып та карамады, саубуллашмады, минем барлыгымны онытты. Бүлмәмә кайтып барганда ят адәмнең кыланмышларын өзелмәс бер җепкә тезә башлагач әсәренеп киттем. Ата-анасына булышырга йөрүе дә, бабасының

татарлыгы да, үзенең «әфганлы» икәне дә (документын чыгарып салды!) – мине йомшату, тел яздыру гына булган лабаса! Бүгенге «Индустриальная Караганда» газетасының беренче битендәге (1990. – 22 август) «Не вижу необходимости» дигән мәкаләдә шәһәрнең Ленин районы халык депутатларының район Советы рәисе урынбасары К. Ташбулатов сайлаучылар исеменнән Караганда шәһәренә шул көннәрдә гаскәр кертү белән асла килешмәвен белдерә. Димәк, Карагандага шушы арада, мин килгән шәптә, гаскәр керткәннәр! Шәһәрдә бу актка каршы протест митинглары бара икән. Казаннан җирле КГБга ни дип шылтыраттылар икән? Мин «архивка керергә булышсыннар» дип әйттерергә теләгән идем. Килгәннең икенче көнендә кизү биргән телефон белән шылтыраттым, «архив документлары» дигәч, трубка шактый вакыт дәһшәтле тынып торды, җаваплы иптәш минем кем булуым белән дә, ни юллап йөрүем, ни эзләүләрем белән дә кызыксынмады, сорашмады, белешмәде, «эшебез бик тыгыз вакыт, вакытым юк» диде.

Алар шушы болганчык көннәрдә Казаннан казахларны котыртырга килгән яшерен эмиссар[1] дип кабул итмәделәрме мине? Эмиссар буласы иде дә... алай түгел шул, түгел! Иҗтимагый хәрәкәттән читтә яшим, олыгайдым, акыл салмакланды, егәр барында, зиһен ачык чакта «программа-минимум»ны башкарып чыгасы килә, язасы әйберләр күп булмаса да, бар... Язарга! Халкым язмышы хәл ителгәндә, миннән өлеш – хак, гадел сүз булыр!

«Туганым» дип кочаклап каршылаган, төкереп киткән казах бәндәсе уйларымны көтелмәгән якка юнәлтте. Бәлки, бу – бер курку гына булгандыр? Белмим...

Бүген, әйткәнемчә, 22 август. Төн җылы, рәхәт булды. Кытайларның чираттагы бунты да колакка кермәде, иртән саф баш белән уянган идем. Сәгать сигездә үк автовокзалга төшеп, көч-хәл белән Волынка таш карьерын эзләп таптым. Әгәр килгән көнне үк, күңел үтә боек, төшенке чакта карьерны эзли чыксам, һич табасы түгел икәнмен. Бүген мин бүтән,

[1] Эмиссар – аерым политик оешмалар яки дәүләт оешмалары тарафыннан яшерен эш белән җибәрелгән кеше.

җаныма үзем хуҗа! Аякны кыра торган ботинка башларына учлап-учлап газета кисәкләре тутырдым да кукраеп йөрим. Аяк адымнары кәефкә карап үзгәрә, текә йөримдер шул, таш базына алып барган такси шофёры: «Сез олы бер начальник булгансыздыр, ахры»,– диде. Көлемсерәдем. Язучы начальник була диме? Начальник та берчакта да язучы була алмый. Язучы – үз халкының рух сакчысы, намусы. Мин шулай була алдыммы? Белмим, иң авыры – үз-үзеңә хөкем чыгару...

Шартлап урталайга ярылырга әзер җанымны чак-чак тыеп, пресс цехына таба барам. Нигә эшләмиләр икән бүген? Беркайда бер кеше заты күренми. Гофман мичләре элекке нигезләрендә утырсалар да, шушы еллар эчендә аларны ничә сүтеп, ничә тапкыр җыйганнар инде! Үземнең дә кирпеч яндыру мичләрен сүтеп җыйганым бар иде. Ишекләр, ишекләр... Берләренең ишекләре томаланган, эчтә чи кирпеч кибә. Арырак үтүгә, ишекләрдән эссе бәрә: монда, дулыйдулый, ялкын йөри, кирпеч яна. Берләре ачык: алардан яндырылган кирпечләрне бушаталар. Тар һәм тәбәнәк ишекләргә сыешлы автопогрузчиклар көйләгәннәр икән. Безнең заманда мичтән кирпеч чыгару – гаять авыр хезмәтләрнең берсе иде! Мич эчендә әле алтмыш-җитмеш градус эсселек, уттай кирпечләрне тачкаларга яланкул төйисең һәм, тимер тасмалардан тәгәрәтеп, ишегалдына чыгарасың, анда штабельләргә шакмаклап өясең... Яланбаш керсәң, мичтә чәч көя торган иде! Һәрбер кирпеч дүрт кило! Тачкага алтмышҗитмеш кирпеч төяргә кирәк. Кимрәк төясәң, нормаң үтәлми. Норма үтәлмәсә, бригаданың паёгын кисәләр. Зың-зың итеп чыңлап торган, алмаздай үткен кырлы Актас кирпечен вагоннарга күпме төядем икән мин? Учлар сыдырылып канап, бармак башларының тиресе кубып, төннәр буе сыкранып, җыламсырап ята торган идек... Бу заводта мин сынамаган хезмәт төре аз калгандыр...

Ниһаять, пресс цехы. Дүрт пресстан бүген берсе дә эшләми. Өч хатын, тузанлы агач рейкаларга утырып, бидоннан кружкаларга чумырып алып, суык чәй чөмерәләр. Алар эндәшми, мин дә тып-тын гына ары-бире йөргәлим... Эшне монда да чак-чак «җиңеләйткәннәр» икән: карыйм, кирпечне автоматлар кисә. Заманында бу чамасыз авыр эшне

бригаданың таза, тыңлаучан егетләре латыш Скуя, эстон Ансонслар башкара иде. Кирпеч заводында бер генә җиңел эш тә юк. Җитмәсә, һәр бригадага җиде-сигез карт-коры кертелгән, аларның формулярларына «использовать на особо тяжёлых трудах» дип язылган. Безнең пресс бригадасында иң өлкән кеше – мәскәүле Ной Борисович Окунь. Гомере буе наркоматларда эшләгән бу җитмеш биш яшьлек кешене кая куясың? Тамак туйдырыйм дисә, бригада аның нормасын да үтәргә тиеш. План үтәү ягын бригадир кайгырта, әгәр ул вольняшкалар – цех мастеры, начальнигы, нормировщиклар белән уртак тел таба алса, эш бераз көйләнә, юк икән – бөтенең өелеп ач утырасың...

Пресслар яныннан карьерга чыга торган ишеккә атлыйм. Өч-дүрт ир стенага арка терәп тәмәке пыскыталар, миңа теләр-теләмәс кенә күз ташлап алалар. Мин аларга да дәшмим. Күрер күзгә сөйкемле генә адәмнәр, арада зыялысы да бар түгелме?.. Балчык эше һәрчак авыр, төтен, тузан, газ... Безгә алмашка кемнәр килеп, кемнәр китте икән? Нинди затлар? Уртак язмыш йөртәме аларны, әллә һәркайсысы үз улагыннан агып төшкәнме? Беләсем килсә дә, әлегәчә мин беркемгә дә эндәшмим, хәтеремне мәңгегә биләгән йөзләрчә шәүләләр озатып йөри мине, сорашмыйм да, алар кайчандыр монда коточкыч язмышка дучар ителгәннәрнең җәһәннәме икәнен бөтенләй белмиләр дә... Автобустан төшкәч, теге юантык хатыннан: «Заводны японнар, немец әсирләре салганын, озак еллар монда тоткыннар эшләгәнен беләсезме?» – дип сорагач, ул миңа акылдан шашкан кешегә карагандай карады. Ә болар – яшьләр, әле ни белсеннәр? Яшьлек тарихны яратмый.

Кире әйләнеп кереп, мичләрнең аргы баштагылары янәшәсеннән барам. Кара-көрән ишекле киптерү камералары. Исләр, төсләр, гомуми манзара таныш, искечә. Безнең цех начальнигы чулак Сергеев иде, мастерыбыз – Григорьев дигән юаш кына, төшенке иңле бәндә. Алар да мондадыр кебек, төтен-газ саркып торган камера ишегеннән безнең хәйлә-туфталарны тотарга куелган, авызыннан сасы махоркасы төшмәгән, ат тешле ярты казах, ярты урыс Ундасынов килеп чыгар төсле. Аныңча итеп: «Эх, французлар!» – дип

пышылдыйм. Болар – вольняшкалар, шулай булса да, бергә эшлибез, язмыш уртак. Завод директоры Белоусовны – Лидия Тимашук[1] Кремль врачларының «битлеген салдыргач», врачларга үлем җәзасын таләп итеп чәчрәп чыккан ыспай киемле, юка, какча кешене –без бик сирәк күрәбез. «Йодрык кадәрле, йомры гәүдәле», карлыгачтай кап-кара, һәйбәт кара тройка кигән баш инженерыбыз яһүд Ройтман, пресслар ремонтта чакта кереп-кагылып чыккаласа да, тоткыннар белән сөйләшми, мөгаен, үзе дә җәза татыган, сөргендәге кешедер, үз ихтыярыннан Карагандага килеп тарымас, ул, гаепле кешедәй, ике-өч минут аякларын алыштырып басып тора да югала. Вольняшкалар безнең белән ныклап аралашмыйлар, тоткыннар алдында үзара сөйләшмиләр диярлек, йомышларны үтәмиләр, почта әрҗәләренә хат сал, дисәң – алмыйлар. Хатларны кирпеч төяргә килгән машина шофёрлары да сирәк ала, ә безнең хат саласы килә, гамәлдәге закон буенча безгә елына ике хат язарга гына рөхсәт, анда да урыс телендә, җитмәсә,– нибарысы ачык хат... Ялынып, ялварып тапшырган хатларның күпчелеген шофёрлар почтага илтеп йөрми, алалар да юк итәләр. Бер-берсеннән курку җелекләргә төшкән. Без хатларны болай да, шомартып, бизәп, таслап, ата-ана, туганнар өстәмә җәфаланмасын дип, чынлыктан ерагайтып яза торган идек. Ни үкенеч! Лагерьның кырыс, ямьсез чынлыгы, сугыш чорында көчсез малай булып җәфа чиккән буынның, үсеп җиткәч, колхоз рәисләрен, явыз коммунистларны, вәкилләрне рәттән пычакка алуларын, лагерьда милләтләрнең бер-берсен кыруларын, шушы уч төбе кадәр лагерьларда бөтен илләрдән тоткыннар булуын, аларның ачыгуларын, нужаларын, унар-унбишәр ел илләре белән бәйләнешкә керә алмауларын хатларда язып булмады. Өйдә әти – укытучы, абыем Азат та мәктәптә укыта, энекәшләр – институтларда, шулар өчен куркылды. Безгә лагерьлардан котылып чыккач та өйгә кайту юк иде, иң зур күпчелек кайту,

[1] Лидия Феодосьевна (Федосеевна) Тимошук (Тимашук, 1898–1983) – совет табибы, кардиолог. А. Ждановны дөрес дәваламау турындагы хаты рәсми совет пропагандасы тарафыннан кыска вакытлы, әмма тискәре нәтиҗәләргә китергән «табиблар эше» кампаниясендә кулланыла.

котылу турында уйламый да, һәркемгә егерме бишәр ел төрмә, биш ел сөрген, бишәр ел хокуксыз яшәүне чәпәгәннәр... Чыккан хәлдә дә мәңгелеккә Красноярск урманнарына урман кисәргә озаталар. Анда балта-пычкы гына түгел, лагерь надзирательләреннән дә кабахәтрәк, кансыз комендантлар, махсус җәзачылар көтә. Киләчәк язмышым өчен дә борчылганмындыр инде...

Кирпеч заводы өч сменалы, сигезәр сәгать эшләргә кирәк. Көндезге сменада без эшләсәк, кичке, иртәнге сменага хатын-кызлар килә. Алар, өч меңнән артык хатын-кыз тоткын, безгә якын гына землянкаларда яши, зонада. Мин озак вакытлар ике кыз белән хат алыштым... Украин кызы Лена Иваненко һәм латыш кызы Дзидра миңа өзлексез хат язып тордылар. Мин дә байтак хатлар яздым аларга, хатларым көчле, тәэсирле булгандыр, Теодор Августович Цеплитисның якташы, иректән үк белеш ханым, көннәрдән бер көнне: «Синең тәбәнәк дустың безнең зонада давыл кубарды, кызлар аның өчен бер-берсенең бугазын чәйнәргә әзер», – дип язды. Хатларымны хатын-кыз зонасында кулдан-кулга йөртеп, җыйнаулашып укыганнарын үземә дә ишеттерделәр. Хатлар сакланмады, зоналарда зур күпчелек мине Алексей Михайлович Неон дип белеп калды, лагерьда синең чын исемең юк, син – номер, теләсә нинди исем сайлап ала аласың, мәсәлән, мин Абдулла Али-казының ахирәт дусты Диманы Сергей Курский дип кенә белә идем. 1954 елның августында Кингир восстаниесенә[1] катнашучыларны Казахстаннан Ванин бухтасына төркем-төркем озатканда, без аның белән Чиләбе төрмәсендә очраштык. Восстание вакытында Кингир зонасында газета редакторы булган очлы борынлы, кара күзлеген бер дә салмаган батыр егетнең чын фамилиясен белми дә калдым...

Карабас, Актас, Волынка лагерьлары минем өчен аерата истәлекле, аерата якын. Актаста мин ике тапкыр яшәдем, зур

---

[1] 1954 елның 16 май – 26 июнендә Казахстанның үзәк өлешендә урнашкан Кингир бистәсендәге Степлаг (Степной лагерь) лагереның өченче бүлегендә сәяси тоткыннар күтәргән восстание. ГУЛАГның Сталиннан соңгы тарихында иң аяныч вакыйгаларның берсе.

мәктәп үттем, акыллы юлдашларым аша мин 50 нче еллар башында ук Ленин-Сталин тәгълиматының җимергеч көчен, социализм теориясенең нигезендә халыкларны хайванга әйләндерү максаты ятканын азмы-күпме белә идем инде. Без булган каты режимлы лагерьларда тел ирege яшәде, сүз өчен эзәрлекләү дигәнне мин хәтерләмим. ВКП(б)ның «Второе крепостное право большевиков» икәнен мин Солженицыннан укып түгел, үз җилкәмдә татып аңладым. Лагерьлар, төрмәләр, кырылышлар мине язучы итеп ныгытты, бер үк вакытта системадан, властьтан курку хисен дә сеңдерде. Бу авыр мәктәп сине бөгә, законнан, власть вәкиленнән курку хисе бүгенгәчә индә саклана, инде аннан котылмак юк. Курку хисе ул — тирән тән ярасы, йөрәк җәрәхәте.

Курку, сагаю, түбәнсенү, буйсыну, «тәлинкә тоту» дүрт йөз утыз сигез ел дәвамында империянең иң түбән катламында яшәргә мәҗбүр ителгән татарга шулкадәр сеңгән — Явыз Иван[1] укыткан «әбҗәд» һич кенә дә каннан китми, буыннан буынга күчә бара. Бәлки, хәлләр үзгәреп, ике-өч буын куркаклыктан арынганнан соң, балаларыбыз, оныклар канында чын болгар, кыпчак горурлыгы, чын татар гайрәте уяныр. Ай-һай, даими һәм дәвамлы, тирәнтен дәлилләнгән, ышанычлы программа белән үткәрелгән селекция кирәк булачак әле моңа.

Мең ел буена кешелек тарихы татарны хурлык баганасына кадаклап, әллә кемнәрнең явызлыгын, кансызлыгын аңа яккан; әле соңгы елларда гына татар белән янәшә яшәгән халыклар, үз милләтләрен югары күтәрер өчен, татар исемен аяк астына салып таптыйлар, татарның милли казанышларын ипләп-ипләп урлыйлар да үз язмышларының нигез ташлары итәргә тырышалар. Мең ел каһәр ишеткән милләттәшләребезнең үз татарлыгыннан борын чөерүенең җитди бер сәбәбе шунда түгелме икән?

Атаклы сәяхәтче Марко Поло «Дөньяның төрлелеге хакында китабы»ның[2] соңгы юлларын 1298 елның икенче

[1] Иван IV Васильевич (1530—1584) — Мәскәүнең бөек кенәзе (1533), бөтен Русиянең беренче патшасы (1547). 1552 елда Казан ханлыгын басып алган.

[2] Марко Поло (1254—1324) — итальян сәүдәгәре һәм сәяхәтчесе.

яртысында Генуя төрмәсендә язып тәмамлаган. Сәяхәтен Венециядән башлап, Судак, Үкәк, Сарай, Болгар җирләрен үтеп, Урта Азия, Ерак Көнчыгыш, Япония, Корея, Һиндстан һ.б. бик күп илләрне, шәһәрләрне кичкән сәях ике юлының берендә «татар» дигән сүзне куллана, бик күп милләт вәкилләрен «татар» дип тамгалый һәм алар кылган яхшылык һәм яманлыкны «татарларга» йөкли бара. Яманлык ташка язылса, яхшылыкның комга язылганын без бик борынгыдан татып беләбез, нәни генә вакыт дулкыны да яхшылыкны юа, оныттыра. Әрмәнстанда да, Грузиядә дә татарлар, «Большая страна Персия, а в старину она была ещё больше и сильнее, а ныне татары разорили и разграбили её», «Балх – большой, знатный город, а прежде он был больше и лучше, татары грабили его и разрушали» һ.б. Заманында Урал аръягында йөзләрчә кабиләләр «татар» исемен йөрткәннәр, Кавказ–Кырым «татар иле» булган, кабиләләр беткән, ә кылган явызлыклары Казан татарларына сыланып калган. Бу буталыш кайчанга кадәр дәвам итәр, ләкин аның бер чиге булырга тиеш ләбаса!

Заводның шактый озынга сузылган юеш, тузанлы бинасыннан чыгып, түбәнгәрәк, без барындагы балчык карьерлары тирәсенә төшеп барам. Күз тирә-якны сөрә, бер ноктада тукталып тора алмый, нидер эзли, капшый... Заманында, төзелә башлаган дәвердә, мин кочегар булып эшләгән шахта ягыннан кап-кара болытмы, дегеттәй төтенме ага. Кара төтен, кайда гына очратсаң да, күңелгә шөбһә, шик-шомнар китерә. Элеккеге балчык ваклау тегермәннәре юк, алар урынында кырык тераүгә калган тишек-тошык сарай хәрабәсе утыра. Завод белән карьерны тоташтырган ябулы галерея да беткән, тәүлек буе безнең канны суырып, кара җылан булып шуышкан транспортёрлар да калмаган. Карьер, әкияти сигезаякның кармавычлары булып, ермач-ермач җәелгән, кая карама – убылып-убылып киткән котсыз, пычрак авызлы кыеш-мыеш чокырлар. Элек монда, без барында, зонаның зур бер өлешендә тип-тигез дала иде. Безнең бригаданың бер

1271–1295 елларда әтисе һәм бертуганы Маффео белән Азия буенча сәяхәт кыла. Ил гизүдән алган тәэссоратларын югарыда телгә алынган китабында язып калдыра.

өлешен (бригадирыбыз Фёдор Лобков, урыс егете) кирпечтән төрле шәкелдәге блоклар ясарга куйдылар. Эссе җәй, карьерның балчыктан бушаган ачык базларына язгы сулар җыелып калган. Без профессор Ростислав Илечко белән ташчыларга – блок җыю осталарына – носилка белән измә ташыйбыз. Теодор Августович Цеплитис – ташчыларның кәттәсе – мине эшкә өйрәтә. «Туфтить итәргә генә өйрәтимме, әллә чын эшне беләсең киләме?» – дип сорый. Мин, аптырап: «Ничек алай була ул?» – дип куям. Теодор Августович, иренмичә, мине завод бинасы янына ук алып менә. Заводның беренче чиратын япон, немец әсирләре сала башлаган, икенче чиратына Европа илләреннән Рәсәй халыклары – үзебезнең ватандашлар – сугыш әсирләре кайтып җиткән. Японнар, немецлар күтәргән стеналар көзге кебек тигез, кирпечләрнең җеге җеккә тоташкан, көлеп тора. «Күр, әсирләр чит җирдә, дошманнарына, урыска эшлибез дип тормаганнар, эшне җиренә җиткереп коеп куйганнар... Ә рәсәйлеләр салган диварны үзең дә күрәсең...» Теодор Августовичның күзе үткенлегенә сокландым. Хәер, илдәшләр салган измәнең дәү-дәү кутыр булып касмакланып катуын күрми калу да мөмкин түгел иде...

Хәзер дала юк, бу тарафның кайчандыр тип-тигез икәнен дә күз алдына китерү кыен. Кайда ул озак вакыт аш бүлешкән немец Һайнц Бем белән шампиньон җыйган уйдык урыннар? Ни генә юк бу пәри кырында? Күптән түгел телевизордан чыгыш ясап, металлургия комбинатларының бер директоры металл калдыкларының җыелмавын, комбинатның икеөч көнлек кенә запасы калганына әрнеп, ачынып сөйләгән иде. Сүзе рас, әле шушы тар гына мәйданда йөзләрчә тонна металл күгәреп, череп әрәм булып ята. Дәү-дәү моторлар, трактор чылбырлары, траплар, өр-яңа арматура бәйләмнәре, төрле размердагы тимерчыбык көлтәләре, калҗайган, кыйшайган өр-яңа станоклар, мин исемнәрен белмәгән әллә ниләр, әллә ниләр... Безне алыштырган буынны эш сөя дип әйтеп булмый, кая ул... Каян килгән шушы кадәр тимер-томыр, нинди кырылышлардан ятып калган?

Мастерыбыз – вольняшка Эдуард Иванович Шатшнейдер җитәкчелегендә кирпеч блокларны кышын да әзерләрлек

итеп, шактый зур цех бинасы сала башлаган идек. Шуның подвалына төшеп барганда, аркылы салынган тимер өрлеккә маңгаем орынды, күтәрелеп карасам, кемнеңдер акбур белән эре хәрефләрдән «О, милая!» дигән язуын күрдем. Җаным тетрәнеп китте...

Бүген монда җимерекләрдән торган бушлык, алай да тимер өрлек аша дәшкән, минем үткәнемне искә төшергән гашыйк күңелне хәтерләдем. «И кеше!» дип иңрәде күңелем, син дә шушы бер сүзең, бер ымың белән мине язучы итеп әзерләштең, юксылларны кызганырга, шәфкатьле булырга, яратырга өндәдең. Рәхмәт сиңа! Синең шигъри ымың кемгә төбәлгәндер, анысын белмим, әндәшең миңа туп-туры килеп иреште, аны мин кабул иттем, җан авазың миңа, мөлдерәмә тулган күңелемә көч, акыллы хис бирде. Бүген, 1990 елның 20 августында, синең бер өнең җир тетрәткән бинаның эзен эзлим. Ул юк, аны да вакыт йоткан.

Актасның таныш күгеннән тып та тып авыр тамчылар егыла башлады, янымдагы букчамнан зонтигымны алмыйм, үз халәтемне берничек тә үзгәртәсем килми. Беләм,раслый алам, кеше җаны да, агач үзәге төсле, бер-берсенә сарган боҗралардан тора. 1990 ел Актасы сискәндереп, илертеп, тынычлана башлаган бәгыремне өзеп, җан үзәгемә тирән, истәлекле киң бер боҗра ясамыймыни?

Калҗайган тимер-томырларны яңгыр кыйный, дөньяның бөтен чүп-чарын җыйган аклы-сорылы ярларын шәбәртә... Һич хәтеремә төшерә алмыйм: безнең заманда текә ярларда керәшә оялары бар идеме, әллә мин үткәннәрдән юкны да эзләп маташаммы?..

Яңгыр ныгытып ук ява, дымлы җиргә меңләгән, миллионлаган язмышларның тирән эз-җәрәхәте убылган шушы ноктага минем дә яшьләрем тама – күз көче кимегән, офыгы якынайган өлкән кеше яшьләре...

Ә шахта ягыннан җилбердәгән сөремле, кара ял җиргә тагын да якыная, заводның теге ягын миннән яшерә, «уйламасын» дип бугай, игътибарымны үзенә генә алырга теләп, һаман көчәя...

Ак балчык базларына сөенеч, юаныч эзләп төшмәгән идем, мәгәр күзгә кычкырып кереп торган тоташ вәхши-

лек, табигатьне бозып, җирнең саф йөзен ерту җан ярасын тирәнәйтте, элеккеге җәрәхәткә тозның иң ачысын, иң зәһәрен сипте. Теге заманда да, бу заманда да Казахстан җиренең төп хуҗалары – империалистлар, басып алучылар, колонизаторлар икәнлеген тагын бер кат раслады.

Иртән дә, әбәдтән соң да өзлексез язып утырдым. Иртәгә, иншалла, Волынканың таш базлары белән кавышуны теркәп куярмын. Карабаска барып җитәрменме? Көннәр ару торса, яумаса, Актас тирәләрен тагын бер кат урармын әле! Барасым килә! Хәзер җирле вакыт кичке җиде тулырга егерме минут. Көндез шәһәр белән танышкалап йөрдем. Карагандага күз ияләшә төште. Уртага матур гына күл уеп, су тутырганнар. Күгәрченнәр коенырга озын улак сузганнар, өстә чиста гына күренгән агымның түбән башында күгәрчен мамыгы гына ага. Димәк, бүтән тарафта күгәрченнәр коенырлык су юк, бар булганнары бу тирәгә җыела икән. Әбәдкә мәгълүм ресторанга кердем. Каршыма тап-таза, базык, байларча киенгән ике адәм утырды. Шикле шикләнер дигәндәй, сак колагымны сузып, тегеләрнең әңгәмәсенә елыштым. Нигәдер тыңлыйсым, ишетәсем килә! Ишетелә: Украинадагы ирек, азатлык өчен көрәшүче «Рух»ны сүгәләр. Безгә гаҗәеп якын «рух» сүзе «хәрәкәт» дигәнне аңлата. Зарланалар тегеләр: «Ленин һәйкәлләрен сүтәләр», «Бетсен КГБ!» дип акыралар... «Әгәр Сталин сау булса, нишләтергә белер иде! Хәзер илдә ул идарә итсә, кешечә яшәр идек!» КГБ кешеләреме? Уртакул хуҗалармы? Монда, миллионнар имгәнгән төбәктә, Сталинны тагын кем юксынсын? Яшьтән үк «пешеп» өлгергән, пионердан – комсомолга, комсомолдан партиягә шуышкан фирка әһелләреме? Утырам, өстәлнең икенче ягындагы кешеләр күз алдымда бергә – кара, шомлы шәүләгә әйләнәләр, һәм ул яктан миңа кара су ага. Ашавым ашау булмады.

Кичке сигез булып килә. Җылы, чалт аяз. Кунакханәдән ерак китәргә куркып, карана-карана йөреп килдем. Утырып тордым. Хатын-кызлар бездәгегә караганда затлырак киенгән монда, кыяфәтләре байларча. Олы чуар төркем булып, инглизләр чыгып басты. Затлы киенгән кәттә казах ирләре белән япон автобусында японнар кайтып төште. Кемнәр?

Нишләп йөриләр? Эшлекле адымнары, олысымак кыяфәтләре, җитди чырайлары ял итүчеләр түгеллеген раслый. Кыяфәтләренә, мөмкинлекләренә, үз-үзләрен тотышларына кызыгып карап торам. Затлылар! Иреклеләр! Байлар! Дөньяның теләсә кайсы почмагына чыгып китә алалар, рухи иреклеләр... Хәзер япон әсирләренең кайда күмелүләре турында сүз куерып килә, бәлки, алар да эзсез югалган иптәшләренең ак сөякләрен эзлиләрдер? Арада Саттаро Тогучи юкмы? Юк, болар – яшьләр, чибәрләр, затлы токымнары чәчрәп күзгә күренә. Спасск лагеренда туксан биш мең япон әсире күмелгәнне беләләрме болар? Спасск газеталарында күренмәде, бу санның әлегәчә матбугатта күзгә чалынганы юк, аны миңа Спасскидан килгән бер төркем бандеровчылар – Иван Копач, Фёдор Попежук һәм Митя (фамилиясен онытканмын) сөйләгәннәр иде. Булган анда хәлләр!..

Караганда, асылда, өч зур лагерь идарәләреннән тора иде. Степлаг[1] – җәһәннәм, Җизказган, Кингир лагерьлары – бакыр рудниклары, шахталар һ.б. Степлагта кешеләр озак чыдамыйлар, ике-өч елдан соң «доходяга»га әйләнеп, Спасск шифаханәсенә кайтып егылалар. Спасскида утыз биш мең ятып авыручылар гына була. Утыз биш мең! «Доходяга – тонкий, звонкий, прозрачный, имеет макаронную походку...» Шулай диләр иде бездә. Авыруларның яртысы Спасскида ятып кала, икенче яртысын, әз-мәз «рәткә китереп», Луглагка[2] куалар. Мин, күзлекле тоткын буларак, Степлагка эләкмәдем, турыдан-туры Луглагка тап булдым. «Спасскидан соң Актас – оҗмах!» – диләр иде Копач белән Попежук.

Заманалар үзгәреп, тоткыннарны таратkач, Газиз Кашапов[3] бер төркем офицерлар белән Спасск лагерь хуҗалыгын корылмалары, бараклары белән МВДга кабул итәргә барган. Кызганыч, Газиз Кашаповның күзе ачылып җитмәгән чак була, ул миңа телгә кертерлек берни дә сөйли алмады. Бер

---

[1] Степной лагерь (Особый лагерь № 4), ГУЛАГ системасындагы сәяси тоткыннар өчен 1930 елда оештырылган махсус лагерь.

[2] Луговой лагерь (Особый лагерь № 9). Сәяси тоткыннар өчен 1949 елда оештырылган махсус лагерь.

[3] Газизҗан Салих улы Кашапов (Кашапов-Үзиле, 1942–1991), язучы, журналист.

фактка игътибар итәргә кирәк: лагерь тоткыннардан бушаса да, биналарны, хуҗалык йортларын бүтән бер оешмага бирмәгәннәр, МВД балансында калдырганнар... Нәрсәне күздә тоттылар икән?..

Күңелем сүрән, сизәм: Нәкыя сәфәремнең барышын уйлап борчыла. Иртәгә тагын телеграмма сугарга кирәк. Килүемнең гыйбрәтле, файдалы һәм үтә дә зарур икәнен ул да белеп торсын. Архивка гына кереп булмады, биргән телефоннары белән шылтыратып карадым. Тагын шул җавап: вакытлары юк, эшләре бик тыгыз. Ни өчен гаскәр керткәннәр Караганда җиренә – билгесез. Газеталар һаман бер чүбекне чәйни: план, үтәлеш, ярыш... Әле алар үзгәргәнче! Гәрчә мин күрешеп, сәлам биреп чыгарга дип кергәч, «Индустриальная Караганда» газетасының баш мөхәррире Э. А. Широкобородов: «Безне гел әрлиләр, бик тиз суллаштыгыз, дип гаеплиләр!» – дип сөйләп утырды. Сәяхәтем хакында мәкалә язуымны үтенде. Ашыкты: ни язасымны, иманымның кайсы тармагын ныгытасымны әле үзем дә белеп бетермим, күңел яктылыкка, чынлыкка омтыла. Якты дигәнең хәзерендә караңгы булып чыгар, чынлык исә бик күпләргә бөтенләй кирәк түгел! Гаскәр керткәннәр икән, бу – чиксез зур вакыйга, сәбәбен халыктан яшерәләр икән, бу – советларның яраткан эш ысулы, хәлләр шәптән түгел дигән сүз!

Тирә-ягымда нидер кыймылдый, нидер оеша, нәрсәнедер таркатырга, кемнедер җәзаларга, куарга, таратырга җыеналар. Совет гаскәре соңгы вакытларда бары шундый яман сыйфатларга гына ия булып калды... Тирә-якта, караңгыда нидер өлгерә, үсә, калка, ә мин гафил! Мин әлеге кунакханә коридорларында бугаз ертып акырган бер төркем сәрхушләрнең күмәк тилерүен тыңлап ятам. Булса да булыр икән тынгысыз бина! Төнката лапыр-лопыр чабалар, ишекләрен ачык калдырып, лыбыр-лыбыр төрле телләрдә сөйләшәләр. Гадәттән тыш хәл уртасында калган кунакханә-утрауда беркемнең ваемы юк, һичнигә исләре китми, миннән бүтәннәр артык дәрәҗәдә бәхетлеме әллә?! Күршеләрме, каршылармы – аерып булмый, хатын-кызлар белән утырдылар. Хатын-кыз кунаклары тел белми, ахрысы, чинашып, шаркылдап, тырмашып, аяк тибеп, кул чабып аңлаштылар. Мәчеләр андый

чакта ямьсез мыраулаша, табигатьләре шундый, адәм улларына таңга кадәр, биржа маклерлары сыман, тик тормаска, үкерешергә калдымы?.. Без лагерьларда, ничә милләт балалары, тел белмәгән очракларда да, тын гына аңлаша, җаннарны уртага салып уртаклаша идек. Шулай, кайгыда тын яши белгән адәм балалары шатлыкта чыдаша алмыйлар, үкерәләр, сикерәләр... Гаҗәп!

Таңда нык суытты: бүлмәм сап-салкын, балкон ишегем шар ачык, ә минем түшемнән бөрчек-бөрчек тир ага... Шигәеп уяндым. Ашказаным сулыгып-сулыгып сыкрады. Кичтән бер шешә кефир эчкән идем. Шулмы? Кыска гомерле кефирны бездә озайтып саталар. Әллә бүтән сәбәбе бармы? Ходаем, читтә чирләргә язмасын. Көн яктырганда, баш авыртып уяндым. Бишенче катка менеп каймак, ике күкәй ашап, бер тустаган сыек чәй эчтем дә автовокзалга чаптым.

Юлым – Волынкага, таш базларына...

Волынкада мин озак булмадым. 1953 елның мартында, Сталин үлгәч, амнистия игълан иттеләр дә, кайбер лагерьларда эшче көчләр таралып, эш урыннары бушап калды. Волынкада таш базларында эшләүчеләрне тулаем азат иткәннәр дә аларга алмашка алты йөз кешене Актастан этапка озаттылар. Арага мин дә эләктем. Май башлары иде. Кешесез тып-тын калган, Актаска караганда күп кечкенә бу лагерьга кичкырын килеп урнаштык. Җәмгысы мин анда ун ай чамасы булдым. 1954 елның мартында безне кире Актаска кайтардылар. Актаска кайткач, мине төзелеп яткан шахтага кочегар ярдәмчесе итеп җибәрделәр, урысча бер авыз сүз белмәгән, белергә дә теләмәгән яшь, озын, каратут чырайлы литвалы белән мин кочегаркада эшләдем. Кирпеч заводына кайтмадым.

Сталинсыз чор башланды.

Яңа урын, яңа эш төрләре, монда эш кирпеч заводыннан да авыррак. Җитмеш-сиксән метр тирәнлектә җәенке бер чокыр, төрле калынлыктагы таш катламнары. Тигез диярлек төптә, пәрәвез җепләре булып, тар тимер юллар кисешкән. Уртада, җиз төсенә кергән ермакта, теш сындырырлык салкын су саркып тора. Төрле яктан текә таш кыялар белән камалган чокыр эссе көннәрдә чыдап була алмаслык кыза,

яндыра. Башка эссе каба. Чыдый алмыйча ятып су эчкәннәрдән байтак кеше шунда һәлак булды. Эштән кайта, вагонкасына менеп ята, иртәнгә җан тәслим кылган, бичара... Тазарак тоткыннар авыр, саллы перфораторлар белән таш катламын кисәләр, шурфлар ясыйлар. Вольняшкалар без югында, аулакта, шурфларга динамит стаканнарын тутырып, ташны шартлаталар. Тоткыннар авыр калуннар, ломнар, тимер чөйләр белән таш кантарларын, адәм күтәрерлек ипкә китереп ваклап, вагоннарга тутыралар. Норма – алты вагон. Вагоннарны тар тимер юллардан этеп уртага илтәсең, санап баручыга тапшырасың, ул вагон кабыргасына тамга сала, вагоннарны авыш эстакадага кертәсең, алар бер-бер артлы, каз бәбкәләре кебек тезелеп, өскә менеп китәләр. Өстә дә вагоннарны саныйлар, таш эскерт өстенә, биеккә менгереп бушаталар. Аста бүтән бригадалар, алар ташны, машиналарга төяп, төзелешләргә озаталар. Ул чакта тимер-бетон плитәләр кулланышка кермәгән, йорт, корылма фундаментларына без чыгарган бут ташын тутыралар иде. Ташның бер өлешен тоткыннар дәү, түгәрәк ваклагычлар аша үткәреп, ике төрле вак таш ясыйлар: эреләре «щебень» дип атала, вагы – «кленец». Вак таш бетон ясарга тотыла.

Эш чамасыз авыр. Сменалар юк. Бер караңгыдан икенчесенә кадәр «надо упираться рогами, пахать»!

Ничек, нәрсә булганын ваклыкларына кадәр хәтерләмим, мине тагын күзлек коткарды, килүгә үк таш арасына төшмәдем, безне кабул итеп алган чыгынкы яңаклы, саргылт чәчле өлкән лейтенант Фунтиков, минем Актаста бригадир булуымны белгәч: «Монда да бригадир булырсың!» – диде, читтәрәк басып торырга кушты. Фунтиков ППЧ начальнигы икән. ППЧ – планово-производственная часть. «Читтәрәк торырга» кушылганнар бара-бара байтак җыелды, һәр лагерь, этап озатканда, көчсез-хәлсезләрдән, гарип-горабадан, филон-ялкаулардан, хулиганнардан, эшлексезләрдән котылырга тырыша. Бригадалар оешып беткәч, Фунтиков кызарынып-бүртенеп сүгенергә тотынды. «Аналарын... аталарын... аллаларын... Актасны әйтер идем: җыен гарип-горабаны, аксак-туксакны, күзлекле шайтаннарны төяп җибәргәннәр».

Ул беркемнең дә исемен атамыйча гына озаклап, тәмләп, катлы-катлы сүгенде. Без мыштым гына тыңлап тордык...

Алтмыш-җитмеш инвалидны җыйдылар да мине бригадир итеп куйдылар. Иң әүвәл зонаны ныгыта башладык! И-и, халыкның кан коеп, тир түгеп тапкан акчаларын кайларга гына чәчмәдек инде без! Юлбасарларга, каракларга, сугыш чукмарларына чәнечкеле тимерчыбыктан турыга койган бер койма да яраган, ә безгә койманың буеннан-буена машиналар үтеп чыга алмаслык авыш чокырлар казырга кушылды. Без, «яңа заман башлана, озакламый өйдә булачакбыз!» дип, таң саен өмет яңартабыз, ә югарыдан килгән начальство, полковниклар, подполковниклар һаман бездән шүрлиләр, үзгәрешләрне бөтенләй сизмиләр. Чокырны башта «сиксән сантиметр тирәнлектә» дигәннәр иде, аннан метрга арттырдылар, бер генерал карап киткәннән соң, чокырларны метр да егерме сантиметр казый башладык. Әле ул гынамы сиңа, койма итәгенә буйдан-буйга «Бруно спирале» дигән чәнечкеле чыбыктан[1] өзмәс бөҗралар таратып чыгарга кирәк иде. Ике кеше, колга кертеп, чәнечкеле чыбык йомгагын әләктереп ала да бөҗралар ясап сүтеп бара. Кем чокыр казый, кем чыбык сүтә. Карьерның биләмәләре зур, әле әйтергә онытканмын, бер кырыйда известь яндыра торган зур-зур мичләр бар, ниндидер биналар төзелеп ята, шунда ук квартирлар да булачак, имеш. Зонаны чит-читләп ныгыткач, безне шул төзелешләргә күчерәчәкләр икән...

Түгәрәк известь мичләренә «Берегись козла!» дип, эстаканың буеннан-буена «Берегись орла!» дип язып кадакланган. Мичнең яндыру режимы бозылса, таш чытырдап эри, күмәк төер булып оеша, аны мич стенасыннан куптарып алу – искиткеч кыен эш икән! Шул эреп аккан таш-төер «кәҗә» дип атала. Түбәндә таш төялгән вагоннар махсус ыргаклар белән корыч троска тагылып, авышлыгы кырык бишилле градус эстакада буйлап бер-бер артлы өскә үрмәлиләр, янәшә рельслардан буш вагоннар аска төшә. Сирәк-мирәк таш төялгән авыр вагоннар, тростан ычкынып китеп, түбән-

[1] Үзара кисешүче берничә чәнечкеле тимерчыбыктан ясалган һәм тарттырып куелган, диаметры 70х130 см, озынлыгы 25 м га кадәр булган цилиндр спираль рәвешендәге койма.

гә ыргылалар. Шул вагон «бөркет» дип атала. Аны күрергә язмасын, Ходаем! «Бөркет» үз артыннан ияреп килгән бүтән вагоннарны тростан йолкып ала, рельстан чыккан вагоннар бушларына барып сылана, алар да үз чиратында, бер-берсен ияртеп, түбәнгә очалар. Аркылы-торкылы убылган, ауган вагоннардан ат башы-ат башы ташлар ядрә кебек оча, бәрелүдән очкыннар чәчри, буш вагоннар, йөклеләр астында калып, коймак булып изеләләр. Аста эшләүчеләр, куркып акырыша-акырыша, як-якка чабалар, унлап-егермеләп вагон түбәнгә төшеп сылангач, җир тетри, эссе чокырда тузан болыты әкрен генә, озаклап иңә... Эш туктала, карьер гүли, чиный, акыра...

Известь төягән чаклар күп булды, җәһәннәм газабы, әмма «кәҗә»нең ничек төшкәнен күргәнем булмады. Әле сүрелеп тә өлгермәгән, эреп ябышкан таш-төер янына кысылып мичкә кергән, көннәр буе лом белән, чүкеч-чөйләр белән җәфаланган тоткыннарның кан төкереп ютәлләүләре, туктаусыз су чөмереп эчеп интегүләре хәтеремдә. «Бөркет» очканны бер күреп калдым — бүтән күрергә язмасын, йа Раббым... Очып барган буш вагон ян басмадан ваемсыз гына төшеп барган ике тоткынның измәсен изгән иде. Кайларда гына сагаламый лагерьда адәм баласын әҗәл?! Чәнечкеле авыш койма өчен дә, Бруно спирале өчен дә бик яхшы түлиләр, норма үтәлә, норма үтәлмәсә, лагерь хуҗалары аксак-туксакның җанын алыр иде! Күмер, цемент, агач төягән вагоннар килсә дә, безне чакырып алалар, бушатабыз, әвеш-түеш китерәбез, әмма төп эшебез — һаман зонаны ныгыту. Безнең эш бара, таш чыгару нормасы гына үтәлми! Алты вагон таш төяү — җанны ала торган, җелекне суыра торган норма. Такы-токы ашап, ел тәүлегендә юньле ял күрмәгән доходягалар тагын да шыраеп калды, кабыргаларын әллә каян санарга була! Безнең бригаданы да карьерга төшерделәр. Без дә ломнар, киркалар алдык, яшьрәкләр, тазараклар таш вата, төйи, чуттан чыкканнар таш катламнар арасындагы балчыкны вагоннарга төяп озата. Бер атна эчендә бригада күтәрәмгә калды. Техноругыбыз Штуккерт дигән немец беркөнне бригадирларны эстакадага, санаучы утыра торган бүлмәгә җыеп алды. Лит-

валы Эдуардс Бринклис, бандеровчы Илья Марусяк, бүтән бригадирлар бар, арага мин дә кысылдым...

План үтәлми, тоткыннар 1953 елның җәе икәнен, язмышларында үзгәреш буласын сизенәләр, эленке-салынкы эшләргә, саулыкларын сакларга тырышалар.

Технорук Штуккерт – печән кибәне хәтле гәүдәсен як-якка авыштырып йөри торган Идел буе немецы, үзе дә күзәтү астында яшәүче сөрелгән адәм – мондый тәкъдим ясады: «План үтәлми, план! Аны үтәмәскә безнең хакыбыз юк. Болай итәбез: арадан җиде-сигез егетне сайлап аласыз, кулларына күсәк тоттырасыз, бригадаларга бүленеп, алар арада йөреп торалар. Элеккеге тоткыннар белән без гел шулай эшли торган идек. Күсәк ул... бөтен планнарны үтәтә!» Мондый сүз ишетеп, бригадирлар югалып калдылар. Күсәк белән тукмаганны моңарчы безнең күргән юк иде. 1953 елда, тиран Сталин үлеменнән соң, бер-беребезне тукмап эшләтәбезме? Колыманы, Җизказган, Кингир, Магадан лагерьларын үткән эшчеләрне ярабызмы?

Бригадамның карт-корыларын карьерга куып төшергәне өчен болай да ачуыма буылып, Фунтиков белән әрепләшеп йөри торган мәлем иде, каян күзем төшкәндер, каян кулыма эләккәндер, берзаман, балта тотып, яман сүгенә-сүгенә каһәрләп, Штуккертны эстакада буйлап өерләп куа башладым. Шөкер, егетләр тиз тотып алдылар. Штуккерт та егет икән, зонага белдермәде, моннан соң безнең бригада тирәсендә бик күренеп тә йөрмәде. Бригадамдагы җимерек кашлы, бөтен битен мамык-йон сарган Чуянов дигән бәндә Фунтиковка әйткән әйтүен, ул да эшне зурга җибәрмәде. 1953 ел! Үзгәрешләрнең «беренче карлыгачлары» килгән көн: чит ил тоткыннарына Кызыл Хач[1] аша илләренә хат язарга рөхсәт булды, лагерьга ак кәгазь, каләм, кара китереп тутырдылар: «Үз эшегезне карауларын сорап, җирле прокурорлардан башлап Генеральный прокурорга кадәр дәгъва сүзегезне яза аласыз»,– дип белдерделәр. Волынкада күпчелек яшьләр иде,

[1] Халыкара Кызыл Хач комитеты – кораллы низагларда һәм эчке тәртипсезлекләрдә авырлыкка очраган кешеләргә ярдәм итүче гуманитар оешма. Ул оешма Халыкара Кызыл Хач һәм Кызыл Ярымай хәрәкәтенең бер өлеше булып тора.

асылда, бандеровчылар[1], литвалы яшелләр[2]. Аерым кискенлекләрне искә алмаганда, тату яшәдек, дияргә була.

Вакыт, әйткәнемчә, берчакта да адәм акылы ирешә алмаган берәмлек ул. Вакытның башы-азагы юклыгы адәм акылын һәрдаим түндергән, гасырлар, формацияләр алышынып торса да, беркем Вакытка хуҗа була алмаган, аны иярләргә тырышкан тираннарның да Вакыт серен ачарга гомерләре җитмәгән. Вакыт — көчкә, акылга, ихтыярга, тылсымның барлык төрләренә баш бирми торган каты берәмлек ул. Бу хакыйкатьне Казахстанда йөргәндә аермачык аңладым. Казахстан бу юлы тагын бер хакыйкатьне — ачы хакыйкатьне каныма сеңдереп озатты...

Милләтнең иң зур байлыгы — Хәтер. Уртак хәтерсез милләтләр, милләт булудан туктап, гавам, халык төркеменә әйләнәләр. Уртак Хәтер уртак җир булганда гына сакланадыр, мөгаен. Милләтләр гап-гади чүлмәк китекләренә дә табыналар, усал заманнар чәчкән хатирәләрне берәмтекләп җыялар. Милләт яшәешендә буыннарның төрлесе булып узган, берәүләр милли дан хәзинәләрен иҗат иткәннәр, буыннар ул байлыкны ишәйткән, тарихның авыр юлларыннан бар булганны түкми-чәчми алга үткән. Тарихның иң аяусыз мизгелләрендә империяләр, тираннар Хәтернең үз властьларына комачаулаган өлешен таптап изәргә, күмәргә тырышканнар һәм күп очракларда максатларына ирешкәннәр. Хәтер — чәрексез[3] хәзинә! Октябрь революциясеннән соң усаллыкта бары тик фашистлар партиясе белән генә янәшә куярлык коммунистларның төп эше шул булды: алар көчләп, алдап-

---

[1] Бандера хәрәкәте — Украина милләтчеләре оешмасы фракциясенең берсе. 1939—1956 елларда (иң актив чоры — 1943—1949 еллар) Украина мөстәкыйльлеге өчен корал белән көрәшкән оешма. Ачыктан-ачык коммунистларга каршы булалар. Икенче бөтендөнья сугышы елларында (1939—1945) нацистик Германия хөкүмәте белән хезмәттәшлек итәләр, күп кенә еврейларны, полякларны һәм совет власте тарафында булган кешеләрне үтерәләр. 1944 елдан Совет Армиясе һәм властена каршы көрәшәләр. Бигрәк тә Көнбатыш Украинада киң танылу алалар.

[2] 1940—1953 елларда (иң актив чоры — 1949—1953 еллар) мөстәкыйль Литва өчен көрәшкән кораллы оешма.

[3] Чәрексез (*диал.*) — чыдамсыз, түземсез.

йолдап, куркытып, асып-кисеп, ялган вәгъдәләр биреп, милләтләрнең Хәтерен аста, коммунистик кара дулкын астында калдырдылар.

Хәтер югалтуларның иң аяусыз мисалы бериш халыкларны үз илләреннән чит җирләргә сөрү булды. Үз илләренә кайтырга рөхсәт ителгәч, төп масса әллә кайчан ата-бабаларының җиренә кайтып урнашкан, ә мин Караганда якларында, автобус тукталышларында байтак кына ирле-хатынлы, бала-чагалы чеченнарны күрдем. Калганнар, яшиләр. Авызларына сугып аңлатып булмый...

Караганда – килмешәкләр шәһәре. Шәһәрнең үз төсе, үз мәгънәсе юк. Мин барында шахтёрлар бәйрәме үтте, 26 август иде. Бәйрәм, әмма милли бәйрәм түгел. Корама халык, вокзалдагы сыман очраклы гына җыйналган гавам. Зәңгәр бәрхет камзуллар кигән өч-дүрт татар хатыны, шундый ук камзул кигән гармунчы ир, әниләренең күтәрмә үкчәле күн итекләрен сөйрәгән, баз бәрәңгесенең үсентеләренә охшаган аксыл чырайлы ике малай күренеп калды. Чыгышларыннан соң яннарына барырмын дип көтеп торганда, җитез генә бер марҗа килде дә тегеләрне өерләп каядыр озатты. Күздән югалдылар. Бәйрәм гел урысча барды, бөдрә чәчләрен картуз астыннан тузгытып җибәргән казах егетләре арасында, шулай ук лампаслы чалбарлар кигән җирле казахлар да казахларның уен җырларын җырладылар, менәргә атлары булмаса да, чыбыркы шартлаттылар. Профсоюз вәкиле вата-сындыра казахча ике сүз әйтте дә, шуннан ары казахча ник бер җыр, ник бер көй яңгырасын...

Килмешәкләрнең беравык уртак язмышлары булуы ихтимал, аларның уртак Хәтере генә була алмый. Чөнки Хәтернең һәрчак милли төсмере була... Казан татарларын Сталин чорында сөрмәделәр. Гәрчә 1944 елда, Кырым татарларын куып җибәргәч, Казан татарларын да Урал аръягына сөрергә, дигән карар кабул ителгән булган. Нидер тоткарлаган, кемдер тыйлыктырган. Моны ачу, ачыклау – киләчәк буыннар эше. 1944 елда татарның язмышы кинәт үзгәрә: университетта татар теле һәм әдәбияты кафедрасы ачыла, консерватория, татар театр училищесы, театрлар гөрләп эшли башлый. Газеталарда урыс маршалларының, генералларының татар

солдатының батырлыгы, антка турылыклы булуы хакындагы хәбәрләре күренә башлый. Озакламый Фәннәр академиясенең чираттагы сессиясенә «Казан татарларының килеп чыгышы» дигән махсус мәсьәлә куела. Казан татарларының тарихын бүтәннәрдән аералар. Шул ук чакта Казан татарларына каршы төркем дә тик ятмый, Үзәк Комитет карарларында татарның милли Хәтеренә нык кына кизәнеп алалар.

Милли Хәтер бары тик үз җирендә бердәм булып яшәгәндә генә саклана ала һәм буыннар дисбесенең бөтенлеген, тулылыгын саклый.

Караганда – килмешәкләр шәһәре, анда яшәүчеләрнең уртак Хәтере юк. Әлегә алар моны белми, аңласалар, шәһәр казах милләтенә – ил хуҗаларына йөз тотар иде.

Килмешәк халыкның Хәтере кыска! Җирле халык та килмешәкләр белән тыгыз аралашкач, аның да Хәтере җуела, ул, үзе дә сизмәстән, хәтерсезгә, килмешәккә әйләнә бара! Ярты сәгать вокзалның иң кайнаган җирендә әйләнәм-тулганам, ничәмә-ничә кешедән сорашам, берәүнең дә «Волынка таш базлары» дигәнне күргәне юк, ишеткәне дә юк икән. Иңнәрен генә җыералар, белмиләр. Затлы гына киенгән, зыялы кыяфәтле ике хатын, кызып-кызып, төзелешләр, нормативлар турында сөйләшәләр иде, яннарына барып, сүзләрен бүлдердем. Йа Хода, кирәкле кешеләр төзелеш материалларына караган ниндидер идарәдә эшлиләр икән. Алар да кырт кисте: «Юк, булганы да юк Волынкада карьерның!» – диделәр. «Киров урамында фәләненче йортта нерудный материаллар белән җитәкчелек итүче бүлек бар, алар янына барып карагыз. Гәрчә өлкәдә унөч карьер бар, Волынкада таш чыгару урыны юк!» «Волынка»,– дигәч, диспетчер хатын кыска гына: «146 нчы автобус!» – диде. Кассада да икеләнеп тормадылар, билет тоттырдылар. Бу ни хәл? 146 нчы автобусны көтүчеләр янына бардым, сораша башладым, тегеләр дә аптыраштa калды. «Волынкада дуңгыз үрчетү комплексы гына бар,– диләр.– Каян килсен анда лагерь? Бутыйсыз, гражданин!»

Берсе – юантык кына марҗа, икенчесе – сынык тешле (ире бүләгеме?) казах хатыны. «Ундүрт ел шунда дуңгыз багабыз, бернинди карьер юк анда, бушаган урыны да юк!» –

дип чатнатып торалар. Җыелган халык безне урап алды. Хәрбиләр бар, кызыл чырайлы, куна җилкәле полковник янында ике капитан, туклар бар, ябагайлар, утызлап кеше булдык. Беравыздан: «Юк таш базлары!» – дип ышандырырга тырышалар. «Тоткын чагымда үзем шунда эшләдем!» – дип әйтеп карыйм, тегеләр миңа айдан төшкән сурәбәткә караган-дай карыйлар... Арадан кемдер: «Сарань тирәсендә андый нәмәрсә юк микән?» – дип, кыюсыз гына әйтеп куйды. Бу сүзне мыекка чорнадым.

41 нче номерлы Актаска йөри торган автобус шофёры белән киңәшеп карарга куштылар. Анда чаптым, шофёр, тар маңгаен каты җыерып, озак кына уйлады, өзеп сүз әйтә алмады. Бик озак эзләнгәч, РТИ заводын[1] телгә алды, «Зират артында андый нәрсә юкмы икән?» – дип куйды.

Кая югалды бу таш базлары? Меңнәрчә кешеләрнең язмышын үз учында тоткан, япон, немец әсирләре ачып җибәргән дәһшәтле Волынка карьеры халык хәтерендә калмаган иде. Карьерның язмышы килмешәкләр кулында. Теше сынык хатыннан башка җыелганнар арасында бер генә төрки дә юк иде. Нибарысы утыз алты ел үткән, мин карьердан 1954 елның мартында киттем. Миннән гөрләп эшләп калды... Онытканнармы? Оныттырганнармы? Дөньяда мин барын искәрмәгәннәр алар! Язучы – илләрнең, җирләрнең, милләтләрнең Хәтер сакчысы икәнен абайламаганнар!..

Урынга барып җиткәч күз күрер дип, 146 нчы автобуска кереп утырдым. Халык ишле, тыгыз; яныма баскан полковниктан кыйммәтле Париж исләре килә, димәк, акчаны мул ала... Барабыз, барабыз... Шул ук чокыр-чакырлар, исемсез чокырлар, исемсез басулар, исемсез сукмаклар. Юк инде монда Карама-куыш урманнары, Басу артлары, Чуал, Чүке үзәннәре... Мөхәммәт Мәһди[2] җырлаган Масра кыры да юк, Кесмәс үзәннәре дә юк. Монда инде шигъри җанлы затлар

---

[1] РТИ – резин-техник эшләнмәләр заводы.

[2] Мөхәммәт Сөнгать улы Мәһдиев (1930–1995) – язучы, әдәбият галиме, тәнкыйтьче. Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1990), Татарстанның халык язучысы (1993).

тумый, килмешәкләр, тормышны тапкырлау җәдвәле генә үлчи алырлык кәрлә җаннар туа. Байлык коллары, җәзачылар, караклар, көчләүчеләр күбрәк килмешәкләр арасыннан чыга да килмешәк рухына баш биргән, иманын алыштырган гавам вәкилләреннән чыга. Барабыз, барабыз, күз тукталып сокланырлык бөтен бер җир юк, иген кырлары да күренми, ватык-потык, актарылган, кайтарылган ертык җирләр, ызаннар...

«Волынский агрокомплекс» дип язылган такта сулда калды, автобус бераз тәгәрәде дә, мин Ново-Дубовка дигән авыл каршысында төшеп калдым. Авыл исеме җанымны җылытмаса да, тактада «Волынка» дигән таныш сүз бар лабаса! Казахстан уртасында «Ново-Дубовка» дигән шөкәтсез, тешкә тия торган битараф исем биргәннәр.

Юлда килгәндә автобуска ике егет утырганнар иде, минем белән алар да төште. О, бәхет! Икесе тиң карьерда таш тишкән егетләр икән! «Тоткын идегезме?» – дип сорарга базмадым. И, бәхет! Дөнья йөзендә Волынка карьерын белүче дә калган икән әле! «Сарань тирәсендә түгелме, РТИ заводы ягасындамы?» – дип эзләшкән шәфкатьле җаннар да кыек атып туры тидерә язганнар. Шулай икән, таш базлары шунда икән! Тиз генә Актаска кайтып, аннан 90нчы автобус белән башта Сараньга барырга кирәк икән миңа...

Киттем. Актас уртасында басып торам. Дубовка егетләре таш базларының урынын аңлатсалар да, мин алар сызган картаны ачык кына күз алдыма китерә алмадым. Аннары: «Ташландык карьерга ничек, нинди юллар үтеп барырга була?» – дип туктаусыз сорашам, авызым тик тормый, һәм, ни гаҗәп, тагын шул ук «белмәүчеләр» боҗрасына кереп батам. Сараньга баручылар шактый җыелдык, күпчелеге Сарань кешеләре, урыс-улак, бүтән милләтләр, казахлар берәү дә юк, берсе дә Волынканы белми, карьер турында ишеткәннәре дә юк икән. Мондый туң килмешәкләр төркемендә һәрчак миһербанлы, ярдәмгә атлыгып торучы бер җан була. Төсе-бите белән яһүдәгә тартым бер ханым кычкырып уйлана башлады: «Таксистлардан сорашып карагыз, алар белсә белер... РТИ заводын искә алдылармы... Ай-һай, белмим...» Карчык

Сарань урамнарыннан РТИ заводына ничек-ничек барырга икәнен аңлатты, автобус номерларын кат-кат кабатлады...

Автобуста бер нәрсәне ачыкладым: «Мин зек – тоткын идем, үзем шунда эшләдем», – диюгә, юлдашларымның мие түнеп китә, берьюлы аңгыраялар... «Нинди лагерь булсын анда? Язмаганны...» Үзем булган лагерьларны санап күрсәтәм, тегеләрне ышандырырга телим. «Караганда, Фёдоровка, Михайловка лагерьларында булдым», – дигән идем, бер ир аламасы мине гаепләргә үк кереште: «Илле ел Михайловкада яшим, бернинди лагерь-төрмәләрне белмим. Булганы юк аларның. Долинкада лагерь булган, хәзер дә бар!» Авызына сугасыңмыни! «Михайловкадан ГШО заводына[1] эшкә йөрдем», – дип әйтеп карыйм, ышанмадылар, тәки ялганчы булып калдым.

Беркем бу тирәдә тоташтан дәһшәтле, канлы лагерьлар булуын хәтерләми, адәмнәр, бүгенге, кичәге өзелмәс ыгы-зыгылар белән чикләнеп, хәтерсез, тарихсыз йомылып яшәп, үзләренең хайван хәленә төшүләрен искәрмәгәннәр. Өченче көнгә әйләнеп кайту, тарих сабакларын тәкрарлап акыл алу юк, аны кирәксенмиләр дә. Хәтер югалган, күмелеп калган. Моның өчен бичара адәм балаларына үпкәләргәме? Әллә аларның кадерсез заманда тарихка, үткәннәренә төкереп карауларын хаклы дип санаргамы? Бүгенге нужалы тормыш тәбесендә тырпылдаган халык әгәр үткәннәрнең карасын да җыеп сакласа, аның йөрәге ничекләр чыдар? Шулаен шулай, хәтерсез калган, үткәннәрнең ачы сабагын оныткан ил өстенә тагын бер явыз тиран менеп атланса? Тираннар хәтерсез: буталыш дәверләрне ифрат яраталар, алар әнә шундый болганчык суның дулкыннары булып өскә калкалар да! Тар маңгайлы Язов[2] диктатор булу турында уйламыймы? Нәкъ үзе инде, коеп куйган, төс-кыяфәте белән ахмак Брежневка охшаган, ике тамчы су кебек...

Лагерьларда чакта үзем дә томана сарык булганмын, Актастан Карагандага чаклы ничә чакрым, дип тә сорамаган-

---

[1] ГШО – тау-шахта эшләре өчен җиһазлар җитештерүче завод.

[2] Дмитрий Тимофеевич Язов (1924–2020) – «Советлар Союзы маршалы» дигән исемгә иң соңгылардан лаек булган (1990), хәрби җитәкче, сәясәтче.

мын инде! «Сарань! Сарань!» дип, мең тапкыр колагымны ярып керсә дә, кайда ул төбәк, кай тарафларга урнашкан, белми калганмын. Безне һәрчак конвой — почётлы эскорт каршылаган, җилкәгә мылтык терәп шулар озаткан, ә без, Сталин сарыклары, кая кусалар, баш иеп, сөрлегеп барганбыз да барганбыз. Юк, бөтенебез сарык булган дип, көфер сүз ычкындырдым! Актастан качкан теге төркемне хәтерлисезме? Үткен, елгыр казах егете К.— төбәкне нык белүче, халык белән үз телендә сөйләшүче. Зонегин диңгезче түгел иде микән? Литвалы шофёр теләсә нинди машинаны йөртә. Толя Кузовкин — кыю, чая, тәвәккәл! Ялгышмасам, Абдулла Али-казы япон шпионы иде, ул ике тапкыр совет чиген үтеп кереп, кире чыга алган, өченчесендә генә килеп капкан батыр егет иде! Алар Актасның да, Сараньның да кайда икәнен картографлардан да шәбрәк белгәннәрдер, мөгаен!

Салмак акыллы шул мин, яхшы уйлар һәрчак соңарып килә. Күт астындагы карьерларның нәни генә координатын да белмә инде! Ә яһүдә юл буе минем өчен борчылып барды, исенә төшерде: туганнарыннан кемдер «җәйге ялын карьер янындагы күл ярында үткәргән икән». Ял урыны? Волынка?.. Теге Дубовкада очраган егетләр нидер бутаганнар, ахрысы, таш базларына дип, мине Казахстан курортына җибәргәннәр икән! Нинди ял?

Юлдашларым җанланды, автобус бәхәс учагына әйләнде, сорашу китте, тегеләй диләр, болай диләр, берсе әйткәнне икенчесе юкка чыгара, баш буталды!

Сарань кешеләре дә мин эзләгән лагерьны белми иде.

Ниһаять, безнең Әлмәт, Лениногорскиларны хәтерләткән төссез шәһәргә барып җиттек. Сарань икән. Уртакул йортлар, ике-өч катлы, янбакчаларда көнбагышлар үсә, автовокзаллары моңсу гына. Яһүдә мин күрмәгәнне күреп алган: «Әнә такси килә!» — дип кычкыра-кычкыра, артымнан теркелде. Таксист ике сүз белән табышмакны чишеп бирде: «Монда бик күптәннән таш чыгармыйлар. Барын бар...» «Барыйк!» — дип ялварам, Карагандага кайта икән, ашыга.

Хәзер мин тыныч, яһүдә карчык һаман мине күзәтә икән, баш орып, аңа рәхмәт укыдым.

Менә мин, такси яллап, карьерга юл тотам. Чечен хатыны шофёрга юлны өйрәтә. Килешенәбез: бару-кайтуга икеләтә түләргә булдым. Тар, җимерек асфальт юлдан барабыз. Каралмаган, ташландык юл. Сулда шактый зур мәйданны биләгән зират кала. Дәү-дәү тәреләр, хачлар. «Ә мөселман зираты кайда?» – дип сорыйм шофёрдан. Ул, аптырап, миңа борыла: «Нинди мөселман?» – «Казахлар, татарлар да күп ич монда, әнә чеченнар да бар икән!» Шофёр елмая: «Һәммәсе бергә аралашып яталар, бездә халыкларны аеру юк». Нигә бу Караганда, Сарань, Актаслар шулай котсыз, дисәм, мәсьәлә ачыкланды, әй: бу төбәк шәһәрләренең милли төсе юк, чиркәү, мәчетләр юк монда, тарихны тотып калган ташлар, биналар юк, әллә адәм уллары яши торган кала, әллә җен-пәриләр аймагы... Иман нуры таратып утыручы, яныннан үткәндә сабырланырга, дөньяның фани икәнен искә төшерергә мәҗбүр итүче гыйбадәтханәләр юк икән бу яңа калаларда. Җаннарын җир белән күк арасында адашып йөрергә очырган догасызлар зиратларда көрмәкләшеп, бергә укмашып яталар икән. Бу имансыз рәт араларына фәрештәләр ничек кунсын? Айлы төннәрдә әрвахлар кабер ягаларыннан кубарылып чыккач, кяферләрне күреп ни уйларлар? Берзаман Казахстанның күмерен чыгарып көл итеп бетерерләр, уран запасы Җир шарында исәпләнгән, күпкә бармас, шәһәр урамнарына тагылган исемнәрнең кем шәрәфенә тамгалануы онытылыр... Ни калыр алдагы буыннарга? Әнә ич, кайчандыр төбәкне таш, известь, вак таш белән тәэмин итүче атаклы карьерны утызкырык елдан соң берәү дә белми!..

Зиратны узгач, уңга – чокыр-чакырлы юлга борылдык. Сулда җәелеп яткан зур күл ялтырый. «Балыклы»,– дип аңлата шофёр. Күлнең аргы ягында – РТИ заводы. Без ава-түнә, чайкала-чайкала барабыз. Юл аулак, дала буш. «Караганниклар кая китеп бетте?» – дип сорыйм. «Себеркегә тунап бетерделәр, калмады». Як-ягыма каранам, машинаны узып алга карыйм, берәр таныш сызык, нокта эзлим. Күккә багам, анда да ят болытлар чайкала. Посёлок та юк. Японнар салган иде аны, шуннан беләм, без килгәндә, посёлоктагы мичләр корым, сөремгә тончыгып утыралар иде. Эзләп караганнар, якын-тирәдәге бер генә мичче дә японнарның серенә тө-

шенә алмаган. Бригадабызда Каськ фамилияле сабыр гына эстон бар иде. Хикмәт иясе иде, валлаһи, белмәгән эше юк... Япон осталары чыгарган мичләргә бер-бер артлы җан өреп чыкты...

Дөрес барабызмы без?

Каршыдагы тауга борылганда, уңда, агачлар арасында таштан салынган, өсте җимерек, тәрәзә урыннары төтеннән каралып торган корылма калды. Чәчрәп исемә төште: «Бу без сала башлаган кибет түгел микән, кайтканда тукталырбыз әле»,– дидем. Алдыбызда нинди ят тау бу? «Карьер анда булырга тиеш»,– дип аңлатырга тырышты шофёр. Шунда? Таш базлары тауда түгел иде ләбаса? «Теге бинаның алгы ягында ике аркасы булса, кибет булыр бу, без, нигезен салып, стеналарын күтәрә башлаган идек»,– дим, һаман шул таш хәрабәгә ишарәләп. Бүтәнчә монда мин белгән, миңа таныш бер генә тотыныр нәрсә дә юк. Юл, борылып-сарылып, текә үргә менә башлады, үлән сарган балчык-таш таучыкларны үттек, һәм машинабыз текә, биек тау өстенә үк менеп туктады. Мин машинадан төштем дә телсез калдым... «Телсез калдым» дип моңарчы да язганым бардыр, бүтәннәр дә адәм баласының соң дәрәҗәдә киеренке, гайре табигый мизгелләргә дучар вакытын шушы сүз белән аңлата торганнардыр. Безнең тормышта андый хөкем чыгарырга җай табылып кына тора. Ләкин мин үз гомеремдә беренче тапкыр телсез калдым. Халәтемне, шул минутлардагы тәэссорат көчен нинди сүзләр белән аңлатырга? Моңарчы мин кулланган сүзләрнең бүген егәре җитәрлекме? Басым көчләре калганмы?.. Сүзләр хыянәтче дә алар, син бер нәрсә әйтергә җыенасың, алар бозылып, буйсынып ишетеләләр. Бүген мин сүзләрдән корыч коярга тиеш, җөмләләрем авыр, саллы һәм үтемле булсын!.. Бүген мин укучымның мине аңлавын сорыйм. Үтенәм! Тәңрем, бүген миңа укучым белән уртаклык бир! Тагын кайда аңлаша алабыз без икәү?! Чын, хак, гадел сүзләремне монда әйтмәсәм, мин кайда әйтәм?! Әгәр укучым мине шушы хәлдә аңламый икән, тагын нигә өметләнергә мөмкин?! Җанымның тәнемнән аерылып, баш очында мең нур җебенә таркалып, янып торуына укучым ышанырмы? Хак, мин мәтәлеп каядыр очтыммы, әллә күз алдымдагы

шомлы упкынга төшеп киттемме, аңышмый калдым. Күз күнеккән, 1954 елда хушлаша алмыйча да китеп барган таш базы шушы хәлгә җиткәндер дип уйламаганмынмы, белмим, мәгәр минем андый дәү, төпсез, тирән чокырны күргәнем юк иде. Иң гаҗәбе, шушы чиксез зур, тын, кешесез чокыр хәзер җанлы иде, аның текә-текә ярлары зәңгәрсу рәшә булып тирбәләләр, меңнәрчә ермаклардан, астан миңа таба мең төрле тавышлар илереп үрмәли иде. Перфоратор чүкечләр гөрли, таш яңакларына чап-чап калуннар очып төшә, вагоннар, рельсларны сытып, такта эстакаданы изеп, җылаша-җылаша өскә менәләр... Шушы җәһәннәм авазлары арасында өрәк сыман тын гына йөзләгән кешеләр эшләп йөри. Күземне кысып, йомып, тавышларны сүндердем, алай да колагым, тирә-ягымдагы көчле басымга чыдый алмыйча, озак кына чыңлап торды.

Аңыма килдем... Мин биектә-биектә, текә ярлар өстендә, очып китәргә тырышып, хәлсезлектән канатларын кага алмаган карт бөркет шикелле талпынып торам. Әгәр бер читкәрәк китеп шым гына чүгәләгән шофёр һәм кызган тимер исе чәчеп торган машина булмаса, мин үземне бүтән бер планетада дип уйлар идем. Аста күзем кочагына сыймаган, киноларда гына күргән, вулкан кратерымы, җир убылганнан калган тирән күл җәйрәп ята. Күл уртасына җыелган акчарлакларны тиз генә абайламадым, әле тирә-якның бер бөртеген дә аерып күреп булмый, дөнья, җир вә күк күзләремә тоташ кереп бетә, нәрсә-каралар, таш-балчык таулар, үләннәр – һәммәсе, сыеклыкка әйләнеп, күзләремә ага... Әллә җылыйм инде?.. Юк икән, мин җылый да алмыйм, җылый алу – җиңеләю тойгысы да югалган... Бераз ияләшкәч, шәп-шәрә ярларны аердым, таш базның төптә калганын аңладым. Таш чыгарганда артып калган балчык, комнардан өелгән икән бу ялган тау. Шушы кадәр балчык артсын өчен күпме таш чыгарырга кирәк булгандыр?..

Без эшләгән чактагы таш базыннан, ичмасам, ник бер багана, ник бер бина, ник бер хатирә калсын, бөтенесе җимерелгән, кырылган, югалган, күмелгән, сүтелгән, ташылган, беткән. Дөньяның дүрт ягыннан берсен дә танымыйм... Ялгыштыр ла, без эшләгән карьер түгелдер бу, миңа юл

эзләшкән йөзләгән җылы җаннар онытканнардыр, саташалардыр гына!.. Карт күзләремнең соңгы өмет нурларын түгеп эзлим, эзлим: унда, зәңгәрсу ераклыкта, тау артындагы үзәндә шакмак-шакмак дача йортлары тирбәлеп утыра. Миражмы? Саташаммы? Теге яһүдә карчык: «Ял иткәннәр, күлдә коенганнар!..» – дигән иде. Әллә шунда төшеп сорашыргамы?.. Анда да шул хәтерсез гавам – килмешәкләр оя кормаганмыни?! Таш базын япон-немец әсирләре ачканын белми булыр алар... Йөзләрчә солдат, офицерларны сыйдырган посёлокны да алар башлап җибәргән. Алла каһәрләгән, шушы ташландык җәһәннәм чокырында меңнәрчә тоткыннарның күпьеллык хәсрәте убылып калганын уйламый да булыр дачник-килмешәкләр! Рәхәт, ваемсыз яшиләрдер алар! Әгәр мин дә шушы таш базның төбендә сөзелеп калган авыр серләрне белмәсәм, йөземне кояшка куеп, шаккатып, ерак офыкларга таң калып торыр идем микән? Монда булып үткән елларның, шул еллар кол иткән буыннарның, үлгән, чирләп егылган, җәфаланган йөзләрнең язмышы минем иңемне басып тормаса, бәлки, мин дә бүтәнчә уйлар идем.

Күңелем ничәмә-ничә еллар иңемә басып торган котылгысыз хатирәләрдән котылырга теләп илереп җылый, күз алдым ачыла дисәм, тагын да куерак караңгылана, мин, аска мәтәлеп төшүдән шүрләп, артка тайчынам. Күкне кояш биләгән, болытсыз, җылы. Күл көзге кояшның уклы нурларын миңа таба кайтара, мин, сукыраеп, күзләремне чытырдатып йомам, йомсам да, тирә-якта минем һәм йөзләгән тоткыннарның гомере, яшьлеге ап-ачык күренеп тора. Бер тавыш, хәрәкәт, кош-корт юк, ятып, үрмәләп, тураеп үскән әремнәр, чәнечкеле үләннәрдән таралган исләр тирбәлә-тирбәлә миңа килеп җитәләр, тирбәтәләр, сабырланырга өндиләр. Шофёр ярга якынрак килгән иде, йодрык таш аска тәгәрәде, әмма суга төшеп җитә алмады, арып, чокырчыкларның берсенә сеңеп оялады. Акчарлаклар мине каршылар өчен теге күлләрдән дә килгәнме? Алар шактый күп, түгәрәк ясап, борыннарын уртадагы буш бөҗрага сузып тирбәләләр. Диңгез акчарлагы – давылда һәлак булган морякларның җаны, диләр. Әллә болары шушы якларда әҗәл тапкан тоткыннарның җаннары микән?..

1953 ел булып, илнең албастысы, канлы тираны Сталин дөмексә дә, әле иске лагерь тәртипләре алышынмаган иде, кеше тулысынча кол иде.

Таш базлары! Таш җәһәннәм! Җәй! Кояш ярдәмче түгел – дошман! Таш үзе дә чамасыз кыза, тимер ломнар, чүкечләр ут булып яналар, һава хәрәкәтсез, таш тузаны бер күтәрелгәч тиз генә утырмый, борын тишекләре, ирен читләре, күз тирәләре касмакланып ката. Кеше, таш базына төшеп ярты сәгать эшләгәннән соң, вакыт берәмлеген югалта, ул үзе дә таш курчакка әйләнә. Сүз әйтсәң ишетми, өскә күтәрелеп карамый, күңелдә уй юк, анда да төссез бушлык, коллык кына... Ачлык эшләтә тоткыннарны, монда патша – ачлык. Бер генә кеше нормасын үтәмәсә дә, бригаданың паёгын кисәләр, берәүнең дә иптәшләрен ач калдырасы килми, ул шушы җәһәннәм мичендә егылганчы яки җан биргәнче эшли. Кирәкми, Штуккертның күсәкле егетләре дә хаҗәт түгел, һәркем яшәргә, гомерен саклап калырга тырыша. Еллар үзгәрер, бәлки, туган илләргә исән-аман кайтып егылырга насыйп булыр... Ачлыкка түзә алган кеше юк, озак еллар туйганчы ашамаган кеше үзенең кешелек сыйфатларын берәмберәм югалта...

«Телсез калдым» дидем...

Ә мин ни көткән идем соң? Ни белән очрашырга омтылган идем? Гомумән, ни эзлим мин бу ташландык сукмаклардан? Булган, кичкән, үткән-беткән, югалган, онытылган. Әллә минем туймас җаным әнә шул «онытылу» белән килешергә теләмиме?! Егерме ике яшьтән егерме сигезгә кадәр, аң иң тере чакта, иман иңеп, белем ныгыта торган дәвердә, минем гомер кирпеч заводының газлы, исле цехларында, таш базларында үтте. Дөрес, ул дәверемне, «тоташ бәхетсезлек чоры» дип тамгалап, сызып ыргытырга җыенмыйм. Ниндидер бер дәрәҗәдә мин үземчә бәхетле дә идем. Әти-әнием исән иде, эшләп ашыйлар, минем кулга калмаганнар... Мин илнең шундый елларын үз күзләрем белән күрдем, ил белән бергә газапландым. Бу дәвер тиз генә кабатланмас, еракка барып карый алмыйм, кабатланса да, ул бүтәнчә булачак, башка төсләрдә. Яшь чагымда иректә эзләгәнемне, тирән фикердәшләремне үзем узган лагерьларда таптым мин.

Төрмә-лагерь юлларын кичеп, истәлек-хатирәләр, әсәрләр язган бик күп авторлар: «Без нахакка утырдык, безне ялган яла аркасында утырттылар»,– дигән фикер үткәрделәр. Ә безнең «особый, без права переписки» лагерьларында, кешенең исеме югалып, номеры гына тере булып калган каторгаларда, аңлы рәвештә совет властен кабул итмәгән, аның белән көрәшергә, совет системасын бетереп ташларга әзерлекле кешеләр утыра иде. Җитмеш процентыбыз әлерәк кенә көрәш кырларыннан тотып китерелгән бандеровчылар, украинлылар иде. Хәзер аларны «милли каһарманнар» дип йөртә башладылар. Ә нигә?.. Литвалылар, латышлар, эстоннар! Сталин тираниясенә көчләп кертелгән илләр... Совет империясенә каршы корал тотып чыккан асыл ирләр лагерьларда юк өчен утыра идеме?..

1951 елның башында Карабас күчеш лагеренда элек ун ел төрмәдә утырып, икенче срогын башлаган грузин Александр Хуродзе миңа болай дигән иде: «Империя җимереләчәк... Совет власте юкка чыгачак! Без лагерьларда бер дә юкка утырмыйбыз...» Рәхмәт сиңа, Хуродзе агай! Синең сөйкемле чыраең, мине карцерга алып чыкканда надзиратель-палачка әйткән каты сүзләрең әле дә истә!..

Үз илләрендә сәяси төрмәләр булмаганга, Рәсәйнең үзәгенә – таш базларына, рудникларга, шахталарга ябылган мадьярлар, болгарлар, немецлар, румыннар Сталинга баш бирмәгән өчен монда китереп ябылган иде. Иран коммунистларын китереп тутырганнар. Әфганстанның бичаралары – чик сакчылары, палач-кызылармеецлар – айлык ял һәм биш йөз тәңкә бүләк алыр өчен, чик буе авылы крестьяннары кырда эшләп йөргәндә, керәләр дә аларны бу якка сөйрәп чыгаралар икән. Алар да безнең арада иде! «Төньякта искиткеч гадел, бай ил бар, ул – Советлар иле!» дигән ялганга ышанып чикне үтеп чыккан ярлы кытай крестьяннары бар! Бер чит тел белмәгән, укымаган, надан кытайларны, егерме бишәр елга хөкем итеп, «особый лагерьлар»га тутырганнар иде. Якын дустым Хан-Жубо! Синең исемнән украин кызларына ничәмә-ничә хат яздым мин. Кайда икән син? Исәнме? Квантун армиясенең[1] соңгы офицерлары! Власов армия-

[1] Икенче бөтендөнья сугышы елларында Япония Император

сендә[1] хезмәт итеп, совет властеның ни икәнен нечкәлегенә кадәр нык аңлаган урыс егетләре! Сугыштан соң илгә кайткан шанхайлылар: Константин ага Дображанский[2], Юрка Кириллов, Спирин! Европадан илгә кайткан урыс дворяны Уклейн, казачий генерал улы Сидоров!.. Сез ярата идегезме совет режимын? Кыскача гына бәяләгәндә, без барыбыз да Сталинның, Ленинның, Ленин нигез салган совет системасының дошманнары идек. Без үзара һәрнәрсә хакында һич куркусыз, ачыктан-ачык сөйләшә идек. Бу минем өчен бәхетле мәктәп булды.

Иректә чакта ук допросларга йөртеп, мине шулкадәрегә китереп җиткергәннәр иде, үземне кулга алырга килгән КГБ полковнигы Катерлига: «Тизрәк төрмәгә илтеп тыгуларын үзем дә тели идем», – дигәч, ул күзен алартып бер карады да: «Дурак!» – диде. Газраил Катерли сүзләремне хәтерли булыр, алай да, кайткач, очратып бер сөйләшергә дип йөрдем, туры килмәде, башта исән икәнен белмәдем, соңыннан исәнлеге мәгълүм булды, моннан бер ай элек кенә Катерли үлеп китте. КГБ архивларында еллар буе казынып утырган профессор Литвин: «Явызларның явызы, кансызларның кансызы булган Катерли», – дип бәяләде. Бу өлкәдә аның белән килешмәү мөмкин түгел. Әйе, җүләр заманнарда акыллы булу кыен, җүләрлекләр дә булды, ялгыш-хаталар да ясалды, авыл малае, тәҗрибә юк, күп нәрсәне белеп тә бетермәгәнмен, әмма лагерь юллары күпне бирде, күпне татыдым, искиткеч аңлы, акыллы адәмнәр белән аш бүлештем. 1950 елның декабрендә Казаннан Карабаска этап белән барганда, Чиләбе, Свердловск, Петропавловск төрмәләрен үтеп, мин дөнья хәлләрен

---

коралы көчләренең күпсанлы һәм көчле төркеме (коры җир гаскәрләре).

[1] Андрей Андреевич Власов (1901–1946) – генерал-лейтенант. Любань һөҗүм итү операциясе барышында 2 нче удар армия белән командалык итә. 1942 елда немецларга әсир төшә. Совет хәрби әсирләре һәм эмигрантлардан торган оешма җитәкчесе сыйфатында СССРга каршы булган «Өченче рейх» белән хезмәттәшлеккә бара. 1945 елда Кызыл Армия тарафыннан кулга алына.

[2] Константин Андреевич Дображанский (1889–1966) – театр артисты. Грузиянең халык артисты (1954). Русия шәһәрләренең төрле театрларында уйнаган.

шактый тулы аңлый алдым: Сталинның канлы тиран икәнен дә, Кировны[1] ни өчен үтерүләрен дә, Серго Орджоникидзе-ның[2] ни өчен үзенә кул салуын да ап-ачык белә идем. Вагон-дашларым – мәскәүле Яков Борисович Цудечкис, сөйкем-ле яһүд Хинчин, гомере буе Тышкы сәүдә министрлыгында хезмәт итеп, гел-гел «болытларга утырып йөргән» карт яһүд Ольгерт, шикләнмичә, курыкмыйча, дөньяның икенче ягын ачып күрсәттеләр миңа. Юлда барганда, берзаман, вагонның өченче сәкесеннән озын, какча буйлы, сеңердән генә тор-ган нәзек муенлы, ләкин искиткеч сөйкемле, ачык чырайлы, татлы телле урыс – рязаньлы Митя Афанасьев килеп төш-те. Аның авызыннан Власов, власовчылар хакында байтак мәгълүматлар алдым. Әсирлектән күп җәфалар чиккән язучы Әнәс Галиев[3] бер очрашканда, «Идел-Урал» легионын[4] телгә алып: «Күпме татарны саклап калды Шәфи Алмас[5]!» – диде. Шәфи Алмасны, Власовларны без берьяклы аңлап вә аңла-тып киләбез, «Идел-Урал» легионы тарихы һәм аны оеш-тыручыларның берсе Шәфи Алмас үз өйрәнүчеләрен көтә.

---

[1] Сергей Миронович Киров (Костриков, 1886–1934) – совет дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе. 1926 елдан ВКП(б) ҮКның Ленин-град өлкә һәм шәһәр комитетының беренче секретаре, Төньяк-көнбатыш бюро рәисе, 1934 елдан ВКП(б) ҮК секретаре.

[2] Григорий Константинович Орджоникидзе (1886–1937) – та-нылган грузин большевигы, совет дәүләт һәм партия эшлеклесе.

[3] Әнәс Касыйм улы Галиев (1920–1996) – язучы. 1942 елда Май-коп шәһәре тирәсендә барган канлы бәрелешләр вакытында чол-ганышта кала. Контузияле хәлдә дошман кулына әсир төшә. 1945 елның апреленә кадәр, союздаш гаскәрләр азат иткәнче, фашист-лар тоткынлыгында була.

[4] Бөек Ватан сугышында Германия кораллы көчләре соста-вында булган һәм кулга алынган татар, башкорт һ.б. милләт хәрби әсирләреннән торган хәрби оешма.

[5] Габдрахман Гыйбадулла улы Галиуллин (публицистикада – Шәфиев, 1885–1954) – татар эмиграциясенең сәяси җитәкче орга-ны – «Идел-Урал» комитетын оештыручыларның берсе. Ул әсир-леккә эләккән татарларга ихластан ярдәм итәргә тырыша. Татар халкының бәйсезлегенә ирешү эшендә Германиянең ярдәменә исәп тота. Ләкин Германиянең СССР халыкларына мөнәсәбәттә андый планнары булмый.

Свердловск күчеш төрмәсенең тимер-читлек камераларын телгә алган идем инде. Үзеңнән тыш әллә ничә читлек тоткыннарын күрәсең анда. Безнең этап сәяси тоткыннар читлегендә. Караклар – шундый ук янәшә читлектә. Аларның тотышларын, кыяфәтләрен күреп, сүзләрен ишетеп хәйран калган, гел-гел чит илләрдә йөреп эшләгән, эче-тышыннан затлылык бөркелеп торган карт яһүд Ольгертның, төймәләре киселгән, арык тәнендә асылынып торган чалбарын күтәрә-күтәрә, күзлеген рәтләп: «И эти люди наши, советские?» – дип сораганы хәтеремдә. Каракларның берсе читлек тимерләре аша кулын тыгып аның борынына чиртте дә: «Не горюй, папаша, смерть Сталина всем нам принесёт свободу!» – дип кычкырды. Игътибар итегез: бу хәл 1950 елның декабрендә булды!

Инде байтак еллар узгач, лагерьдан котылып Казанга кайткач, 1955 елның көзендә, Ибраһим Нуруллин[1] белән Ленин бакчасында очрашып (кирәк бит, урыны ЧК б업алары каршысында!), мин аңа лагерь сабакларының кайберләрен сөйләп биргән идем. Ленин-Сталин хакында кайбер фикерләремне әйттем мин аңа, Киров, Орджоникидзе, миллионнарның язмышына кагылышлы фактларны телгә алдым. Ортодоксаль Ибраһим Нуруллинның чырае каралганнан-карала барды, ахырда ул түзмәде: «Үзгәрмәгәнсең икән, лагерь төзәтмәгән!» – дигән нәтиҗә ясады! Әле синең «лагерьлар төзәтә» дип ышана торган беркатлы чагың иде. Мондый хөкем чыгаруыңа үпкәләмим, рәнҗемим дә, мине аңлавыңа гына сөенәм. Әйе, бергә укыган елларда ук син минем уй-фикерләремнең кая таба юнәлгәнен беләп идең, минем хакта сорашу өчен сине Черек күлгә[2] чакырмый калмаганнардыр.

[1] Ибраһим Зиннәт улы Нуруллин (1923–1995) – язучы, әдәбият галиме, тәнкыйтьче, профессор. Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1982), Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе (1992).

[2] Черек күл – XIX гасыр урталарына кадәр Казанның үзәгендәге күлне шулай атаганнар. Суы пычрану сәбәпле, 1859 елда күлне күмәләр, һәм ул урын ял паркы булып кына кала. Уң Черноозёр (бүгенге көндә – Дзержинский) урамына НКВД органнары килеп урнашкач, эчке төрмәсе дә булган хокук саклау органнарының

Ләкин син якты йөзле булып калдың, беребезнең эшендә дә синең гаепләү күрсәтмәләрең юк. Бу фикеремне, монда калган иптәшләрнең күзе дөрес ачылсын, дип теркәп китәм...

Волынкада минем бригадада гаҗәп шәхесләр бар иде. Маршаллар, генераллар юк иде югын, әмма Глинканың «Сомнение»сен[1] җанга үткәзеп җырлаучы аксак, табак битле, күзлекле Каськ Мееме Оскарович үзе ни торырлык егет иде! Кулыннан килмәгән эше юк, балта остасы, ташчы, буяучы... Аның кулалмашы эстонлы Койк? Аз сүзле, горур латыш Романас! Мадьярлар Иштван Полачек, Немеш! Литвалы якыннарым: Борис Меркис, Людгарис Пакарклис! Медишаускас Иозос Йона! Кулын кесәләренә тыгып җил-җил йөргән яшь шагыйрь Бүре! Синең «Кас ниекад» («Как никогда») шигырен укуың һаман да колак төбемдә... Мине улы кебек итеп кадерләп йөргән сөйкемле, тыйнак урыс Иван Лапаев!

Сезне юксынып килдемме шушы җәһәннәм авызына?! Мөгаен, шулайдыр. Ниһаять, килеп җиттем, эзләп таптым. Әле зиһенем ачык, хәтерем нык, бик күп юлдашларымның исемнәрен, төс-битләрен хәтерлим. Лагерьда берәүгә дә үткәннәрне ачылып сөйләү юк, сорашмыйлар да, ләкин мин белгән кадәресе дә җитәрлек... Әгәр минем күз алдыннан үткән вакыйгаларның төбенә төшеп, анда катнашкан шәхесләр үткән юлны бәян итә калсаң... Юк-юк, бу – бер кеше кулыннан гына килә торган хезмәт түгел. Тарихның дәһшәтле җилләре безне дала дүңгәләкләрен өерләп йөрткән кебек йөртте. Көне килде – без тагын күрештек менә.

Уйларыма йомгак ясап, җылы җил бөтерелеп алды, сирәгәйгән чәчләремне күземә төшерде. Тирә-ягым ачы әрем генә. Аларның биек-биек үскәннәре бар, үрмәләгәннәре аягыма урала. Төрлесеннән учма-учма сындырып алып, тү-

---

тулы бер комплексын халык «Черек күл» дип атап йөртә башлый. Совет чорында исә ТАССР Дәүләт куркынычсызлыгы комитетының төп бинасы шунда була. Бүгенге көндә Русия хөкүмәтенең Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы урнашкан.

[1] Рус композиторы, милли композиторлар мәктәбенә нигез салучы Михаил Иванович Глинканың (1804–1957) атаклы «Сомнение» романсы (1838).

шемә кысам... Кыргый дала исләрен саклаган әремнәр күңелемне нечкәртәләр, мин, егылып китмәс өчен, ярдан читтәге таучыкка бөгелеп, илереп үксеп җылыйм. Тыелып булмый, тыелырга теләмим дә. Торкын юлдашларымның күбесе инде бу дөньяны куйганнардыр, арада өлкәннәр, чаллар, нужа камытын күпме еллар муеннарыннан төшермәгәннәр бар иде. Дога укып, аларның бәхиллек көткән җаннарын җылыта алмадым, мөселманнар, христианнар, католиклар, лютераннар, яһүдләр – шимбәгә баш оручылар – Букоемский белән Безродный һәм буддистлар! Мине ишетәсезме?! Шушы җәһәннәм чокыры өстендә очып йөргән саф җаннарыгыз хөрмәтенә мин бүген сезгә татарча гына эндәшәм! Саумысыз, туганнарым! Кадерлеләрем! Мин сезне сагынып килдем монда!

*Караганда–Казан–Переделкино*
*1990, август–октябрь*

## Заман мине узып бара[1]

*(Мәкалә)*

*Чорлар алышынганда. Чорлар алышынган чак. Егерменче гасырны түгәрәкләп, яңа меңьеллыкка аяк баскан чак. Татар дөньясы ничек каршылый бу чорны? Мөгаен, бу турыда иң хак, иң мәгънәле сүзне безнең олуг әдипләребез – халык язучылары гына әйтә аладыр. Менә шуңа күрә дә «Zaman-Татарстан» алар сүзенә, алар фикеренә урынны газетаның иң түреннән бирә. Сөйләшүне Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев башлый.*

Без инде бу соңгы егерменче гасырны, гасыр башыннан алып бүгенге көнгә кадәр, бөтенесен күз алдына китерә алабыз. Һәркем үз урынын тапкан, шушы гасыр әдәбиятының нигезен ныгыткан, ниргәләрен биеклеккә күтәргән әдәбият ул Тукайдан башланган. Ул Фатих Әмирханнан[2] башланган. Шулай дәвам итеп, килеп җиткән Әмирхан Еники, Гариф

[1] Әлеге мәкалә «Zaman-Татарстан» газетасының 2000 елгы 22 сентябрь санында басыла.

[2] Мөхәммәтфатих Зариф улы Әмирханов (1886–1926) – язучы, әдәбият тәнкыйтьчесе, җәмәгать эшлеклесе.

Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Гомәр Бәшировка[1]. Татар әдәбияты халыкның күңеленә урнашып, гомер-гомергә укучыны яктылыкка өндәгән. Аның аңына асыл әхлак кагыйдәләрен, тормыш итү кануннарын сеңдерә килгән.

Соңгы ун ел татар әдәбиятының иң авыр еллары булды. Чөнки без әдәбиятның бөтен авырлыгын үз җилкәләрендә күтәреп барган бик зур талантларны югалттык. Иң соңгы югалту Гариф Ахунов булды. Инде җае чыккач, Гариф турында берничә сүз әйтмичә кала алмыйм. Кайбер алап авызларга ияреп, без Гарифны әзрәк кенә кимсетеп килдек. Аны, җиңелрәк яши торган кеше, дип, үзара сөйләшкәләп йөрдек. Хәзер менә Гариф киткәч уйланам: Гариф татар халкының бик күренекле, бик олы улы булган икән. Ул озак еллар Татарстан Язучылар берлеген җитәкләде. Берлекне җитәкләү – ул бит әдәбиятны җитәкләү генә түгел, ул бик күп кешеләрнең язмышын да хәл итү. Кайберәүләр Гарифны Мәскәүдән килгән кешеләргә «тәлинкә тоту»да гаепләделәр. Ләкин бит Мәскәүдән килгән кеше – кунак ул, башка республикалардан килгән кеше дә кунак. Аны кемдер кабул итәргә тиеш. Кемдер аңа хезмәт күрсәтергә тиеш. Ниһаять, кемдер аның тамагын кайгыртырга тиеш. Менә шундый эшләрне Гариф соң дәрәҗәдә югары итеп оештыра белде. Үзебезнең язучылар өчен дә күп эшләде. Үзен үзе жәлләмәде. Һәм, гомумән, Гариф Ахуновның кылган яхшылыклары турында без бик озак елларга кадәр кайта-кайта сагынып сөйләрбез әле.

Гариф ач-ялангач елларда укыды. Бик яшьли үз көнен үзе күрде. Ләкин ул берчакта да язмышыннан зарланмады, тормышның ямен-тәмен таба белде, тапканын кадерләп тотарга өйрәнде. Искиткеч тыйнак, кеше сүзенә һәм гамәленә игътибарлы бу егетебез берзаман күтәрелеп китте. Бик яшьли Язучылар берлегенә кабул ителде. Берсеннән-берсе мавыктыргыч әсәрләр иҗат итте. Ике мәртәбә партия съездларына делегат итеп сайланды. Ике чакырылышта Югары Совет

[1] Гомәр Бәшир улы Бәширов (1901–1999) – язучы, җәмәгать эшлеклесе. ТАССРның халык язучысы (1986), Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге әдәби (1993), Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт (1996) премияләре лауреаты.

депутаты булды. Ни кушсалар, шуны үтәде. Ләкин берчакта да үзенең гражданлык йөзен югалтмады, татар халкының олы бер улы булып кала белде. Мең мәшәкате өстенә туктаусыз иҗат итте, үз укучысын тапты.

Менә бу көннәрдә татарның шушы зур әдибе Гариф Ахуновка 75 яшь тулган булыр иде. Әмма озак еллар янәшә яшәгән дустым бу юбилеен уздыра алмады.

Мин инде хәзер әдәбиятны, элекке шикелле, тулысы белән укып бара алмыйм. Әмма мин беләм: яшьләр арасында да кыю гына язып килүчеләр бар. Ләкин Мөхәммәт Мәһдиев кебек, Гариф Ахунов кебек якты, зур шәхесләр әлегә юк. Әдәбиятта ниндидер бер торгынлык чоры. Заманында, әйтик, Мөхәммәт Мәһдиев ни генә язса да, ул шунда ук үз укучысын таба иде. Язучылар арасында да үзара теләктәшлек уята торган иде. Хәзер андый кеше бармы ул? Әйтә алмыйм. Әдәбият вакланды, дисәң дә дөрес булыр. Әдәбият кечерәйде, дисәң дә хата булмас. Ләкин табигать бушлыкны сөймәгән кебек, әлбәттә, безнең урынга да кемнәрдер килер...

Бүгенге әдәби процессның төп казанышы – татар тарихының яңа ачылган фактик материалларына таяну булыр дип өметләнәм. Без дөрес татар тарихын белмичә үстек. Бер генә мисал: рус шовинистларына ияреп, аларга ярарга тырышып, бөек дәүләтебез Алтын Урданы пычракка батырып, тузга язмаган сүзләр сөйләп йөрдек. Тарих белән ныгытылмаган әдәбият, әдәби әсәрләр белән көчәйтелмәгән тарих берчакта да халыкның иманы була алмый. Әдәбият тарихка иң ышанычлы терәк булып хезмәт итә һәм киресенчә.

Ни кызганыч, безнең буын әдипләре бөек тарихыбыздан мәхрүм булып яшәде. Хәзер татар әдәбияты кискен борылыш ясарга бурычлы. «Кубрат хан»[1] романы белән дәрәҗәсен бик югары күтәргән М. Хәбибуллин[2], тарихи романнары белән

---

[1] М. Хәбибуллинның тарихи романы (1985).

[2] Мөсәгыйт Мөдәррис улы Хәбибуллин (1927–2019) – язучы, публицист. ТАССРның (1977) һәм РСФСРның (1987) атказанган мәдәният хезмәткәре, Россия Язучылар берлегенең әдәби бүләге (1984) һәм Кол Гали исемендәге Халыкара (1996), Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт (2003) премияләре лауреаты, Татарстан Республикасының халык язучысы (2008).

кыю эш итә башлаган Флүс Латыйфи[1], Вахит Имамовларга[2] кызыгып карыйм. Нинди иҗади киңлекләр ачылды алар өчен. Яз да яз гына. Акыллы ханнар да булган татарда, зирәк дин эшлеклеләре дә яшәгән. Һәр буын үз батырын тудырган. Моңарчы без аларны күрә генә белмәгәнбез.

Мин күбрәк проза турында уй йөртәм. Чөнки шигърият дөньясының көче кимегәне юк. Төрледән-төрле шагыйрьләрнең иҗаты күз алдыбызда чәчәк ата. Исемнәрен санамыйм. Поэзия яши, алга таба да яшәр дигән өметтә калам.

Ни кызганыч, соңгы ун елда татар әдәбияты күп укучысын югалтты. Моның сәбәбе берничә. Беренчедән, без кара тартма – телевизор белән ярыша алмыйбыз. Хәзер иң ерак авылларга да телевизор барып керде. Һәм ул мавыгучан татар халкын йотып кына алды. Хәзер инде татар апалары бергә очрашып сөйләшә башласа, татар әдәбиятының соңгы сулышы, йә булмаса, «Сөембикә»[3] журналында басылган хикәяләр турында сөйләшмиләр. Алар бүген арзанлы сериаллар, төче ялганга корылган, бик җиңел кабул ителә торган һәм бик тиз онытыла торган фильмнар турында сөйләшәләр. Чөнки алар, шул фильмнарны карап, үзләренең әдәбиятка булган ихтыяҗларын канәгатьләндерәләр.

Дөрес, халыкның кесәсе саегу, ә китап-журналларның бәясе арту да сәбәп булгандыр халыкның аз укуына. Әле безнең татар бераз булса да укый. Ә руслар гомумән укымый. Рус басмаларының тиражы ул әле алар укыган өчен түгел. Аларны, нигездә, яһүдләр укый. Шулар яза, шулар языла һәм укый. Русның әдәбиятын, мәдәниятен Рәсәйдә бүген яһүдләр күтәреп бара.

---

[1] Флүс Фатих улы Латыйфи (Латыйпов, 1943–2010) – язучы. Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (1993).

[2] Вахит Шәйхенур улы Имамов (1954) – язучы, публицист. Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (2002), Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2014).

[3] Хатын-кызларның бөтентатар иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис журналы. 1926–1940, 1958–1991 елларда – «Азат хатын», 1991 елдан «Сөембикә» исеме белән дөнья күрә.

Халык кабат кайтырмы китапка? Моны әйтүе бик кыен. Бу хакта «Казан утлары»[1] журналында Равил Фәйзуллинның[2] бик акыллы мәкаләсе булды. Ул татар китабының язмышы турында бик борчылып яза. Халык, гомумән, бер татарда гына түгел, башка милләтләрдә дә бизде китаптан. Шулай да мин, элекке кебек ябырылып укыган чорлар яңадан кайтмас, димим.

Яңа тарихи шартлар, яңа икътисади мөнәсәбәтләр, яңа дәүләтләр бөтенләй яңа татарларны тудырачак. Әдәбиятта да ниндидер яңа формалар туып, әдәп-әхлак нормалары яңача яктыртылачак.

Инде үзем турында берничә сүз. Байтак еллар язмыйм. Шуңа күрә мин хәзер, кайта-кайта, үткәннәрем, язган әсәрләрем турында уйлыйм. Кыю булырга тырышылган. Намуслы булып калырга омтылганмын. Менә хәзер, «Мин батыр идем!» дип, бик күкрәк кагасы килә, әмма күкрәккә сугарга йодрык йомшак, күкрәк читлеге дә ул кадәр каты, нык түгел.

Соңгы ике романым – «Йәгез, бер дога!»[3] һәм «Балта кем кулында?»да[4] мин тыелып килгән фикерләремне, әйтергә теләп тә телемне тешләп, туктап калган уйларымны ачыктан-ачык, һич үзгәрешсез яза алдым, дип ышанам. Аларның басылуы да дөньяның әзме-күпме үзгәрешләр башланган чорына туры килде. Рус әдәбиятында да бик зур үзгәрешләр башланган иде бит инде. Руслар, үзләренең чит илләрдәге язучыларын кайтарып, әдәбиятларын яңарттылар, баеттылар.

Уйланган әсәрләрем бар, әлбәттә. Ике-өч повестем, бер романым уйланган килеш тора. «Аръякта, басма чыккач та» дип исемен дә куйган бик шәп повестем бар. Инде һәрьягы

[1] Әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал. 1922 елның маеннан татар телендә нәшер ителә. 1922–1930 елларда – «Безнең юл», 1930–1932 елларда – «Атака» һәм «Яңалиф», 1933–1965 елларда – «Совет әдәбияты», 1965 елдан – хәзерге исемдә.

[2] Равил Габдрахман улы Фәйзуллин (1943) – шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе. ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1976), РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1985), Татарстан Республикасының халык шагыйре (1999).

[3] А. Гыйләҗевнең 1991–1993 елларда язылган роман-хатирәсе.

[4] А. Гыйләҗевнең 1988–1989 елларда язылган романы.

уйланылган. Ләкин мин инде аларга керешә алмыйм. Кереп китә алмыйм мин аңа. Чөнки кемгә адреслыйм мин ул уйларымны? Бүген мин аны кабул итә торган укучыны күрмим. Мин монда бер халыкны гына, укучыны гына гаепләмим. Монда минем үземнең дә гаебем бардыр. Мин, бәлки, заманга ияреп бара алмыймдыр. Заман мине үтеп киткәндер. Бу халәт – язучы өчен үзе бер фаҗига. Гомумән, безгә замана авыр килде. Инде язарга тулы иркенлек ачылды, офыклардан кара болытлар тарала башлады, дигәндә генә, халык үзгәрде дә куйды. Югалттык без укучыны.

Форсаттан файдаланып, бер фикеремне әйтеп калдырыйм әле. Заманында, үзем яшьрәк вакытта, мин әдәбият турында, әдипләр турында бик кискен фикерләр әйткәнмен. Кайбер кешеләрне хаксызга кимсеткәнмен. Мин бөтен кешене дә үзем шикелле итеп күз алдына китергәнмен, күрәсең. Ялгыш фикерләр дә киткән. Бигрәк тә драматурглар хакында. Сәет Шәкүров[6] гомере буена миңа үпкәләп йөрде. Аңа карата мин дә хаксыз булганмын. Сәет Шәкүров[1] бит ихлас драматург иде. Бар иде аның зур гына пьесалары. Хәй Вахитка[2] да минем бик үк дөрес булмаган бәяләр биргән чакларым булды.

Шуңа күрә мин үзем язган әсәрләремне, истәлекләрне, язган хатларның күчермәләрен саклыйм, аларны хәзер үз киштәмдә генә тотам.

Мин бит ниндидер бер дәрәҗәдә рәнҗетелгән әдип идем. Бервакыт иптәшләрем-чордашларымнан ике кеше – инде минем «Өч аршын җир»ем[3] язылган, пьесаларым бар (бик җитди «Киек Каз Юлы»[4] пьесасы да язылган) – чираттагы премияләрен алгач, миңа: «Аяз, сиңа да бүләк алырга чират җитә, әйеме?» – диләр. Менә ничек карыйлар иде бит. Димәк, миңа әле чират җитмәгән булган... (Ә алар үзләрен миннән өстен итеп сөйләшүләре иде.) Дөрес, соңрак, бер ун

[1] Сәет Габделхәй улы Шәкүров (1917–1989) – язучы, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1970).

[2] Габделхәй Каюм улы Вахитов (1918–1978) – язучы. ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1960), ТАССРның (1968) һәм РСФСРның (1980) атказанган сәнгать эшлеклесе.

[3] А. Гыйләҗевнең 1962 елда язылган повесте.

[4] А. Гыйләҗевнең 1960–1961 елларда язылган драмасы.

ел эчендә, мин бөтен премияләрне дә алып бетердем. Ләкин соңрак килгән бәхет әзрәк күңелне китекләндереп өлгергән иде шул. Бәлки, мин шуңа күрә кемнәргәдер рәнҗеп, исемнәрен атамыйча гына, шул рәнҗешләремне көндәлекләремдә, язган хатларымда беркетеп барганмындыр. Гаепләштән булмасын, чордашлар, мин кайберләрегездән гафу сорыйм.

Мин, дөньяны аңларга тырышкан кебек үк, һәркемне аңларга тырышам. Һәм ниндидер бер дәрәҗәдә әдәбиятка безнең барыбызның да кирәкле икәнлегебезне тоеп яшим. Әдәбият тигез дәрәҗәдәге талантлардан гына тормый. Ул әнә шул әдәбиятны сөюче энтузиастлардан да тора. Алар да кайвакытта бик кыйммәтле фикерләр әйтәләр. Шуның өчен әдәбият тарихчылары, тәнкыйтьчеләр, акны карадан аерып, чын талантларга үз бәяләрен биреп, энтузиастларга да игътибарлы булсалар икән. Әдәбият өчен бу гаять файдалы булыр иде.

*2000*

## Үзем[1]

*(«Яра», повестьтан өзек)*

Кеше гомере үтә кыска, саескан гомерен биргән дөнья адәм баласына. Кеше туа, исәя башлауга ук, ул «үлем, әҗәл» дигән хәтәр сүзләрнең серенә төшенә, якыннарының, белешләренең бу дөньяны ташлап китүләрен күреп, ишетеп яши. Гомернең чикләнгән икәнен, көннәрдән бер көнне үзенең юлы киселәсен дә аңлый. Үләсен белсә дә, кеше берчакта да үлем турында уйлап яшәми. Кеше җир йөзендә үлемсез

[1] А. Гыйләҗевнең 1984 һәм 1988 елларда язылган повесте. 1988 елда әсәрдән бер өзек «Татарстан яшьләре» газетасында (9 октябрь, № 41), 1989 елда тулысы белән «Казан утлары» журналында (№ 2, 8–70 б.) басыла. 1991 елда җыентыкта басылып чыга. «Яра» повестеның инсценировка авторы – М. Гыйләҗев. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә 2004 елның 16 гыйнварында шул исемдәге спектакльнең премьерасы була (режиссёры – Р. Фазлыев), 2006 елны Түбән Кама Татар дәүләт драма театры да (режиссёры – Р. Галиев) сәхнәләштерә.

мәгънәләр, мәңгелек барын белә, шулар белән юана, яшәешен бизи, онытыла.

Мәңгелек – безнең изге җиребез, зәңгәр планетабыз. Мәңгелек – безнең зәңгәр күгебез, мәңгелек нурлы кояш, ягымлы-ягымлы ай, гомеребезне бизәп, бәйрәм ясап балкыган сансыз-исәпсез йолдызлар. Иделебез, сыгылмалы матур телебез, моңыбыз, Тукай, Сәйдәш[1]... Безнең күңелләргә Бетховен[2], Шаляпин[3], Григлар[4] да иркен керә, океан-диңгезләр, елга-дәрьялар, Кавказ-Кырым таулары да сыя, алар да синеке, син – кеше, синең күңелең күпне тели, күпне үз итә ала. Җан диләр, йөрәк диләр, татар халкы шулар уртасына Күңел дигән серле дәрья урнаштырган. Кеше Күңеле күзгә күренми, барлыгы беленми, әмма ул бар. Күңел кеше белән бергә туа, бергә ярала, әле ул буш була, тора-бара, тормыш тәҗрибәсе, хисләр, тәэсирләр, мәхәббәт белән байый. Күңелнең буш калу ихтималы да бар, бусы – кеше өчен иң зур фаҗига!

Кеше табигатендә Мәңгелеккә омтылу хисе туганда ук салынган инде, бала туа, йөрергә, йөгерергә өйрәнә, беркем әйтмәсә дә, сурәт ясарга тотына. Кулына ни эләксә – күмер кисәгеме, акбурмы, чыбык кисәгеме – стенага, мич акшарына, урам комына, яр балчыгына, ак кәгазьгә иң әүвал Кеше сурәтен сызгалый, йорт рәсемен төшерә. Кыеш-мыеш була аның йорты, тәрәзәләре авыш-авыш, морҗасы кыек, морҗадан чыккан төтен ат койрыгы сыман таралып китә, мәгәр инде бу – чын йорт. Йорт янында үзе. Бу йорт – баланың яшәргә, тормыш итәргә, бәхет эзләргә омтылышы дигән сүз. Кеше яшәргә тели икән, мәңгелеккә омтылмыйча, чын тормышын кора да алмый. Мәңгелеккә омтылу аның канына, күзәнәкләренә сеңгән, яши-яши, шушы омтылыш аның

[1] Салих Җамалетдин улы Сәйдәшев (1900–1954) – композитор, татар профессиональ музыкасына нигез салучы. ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1939), Татарстанның халык артисты (1951).

[2] Людвиг ван Бетховен (1770–1827) – күренекле алман композиторы, пианисты.

[3] Фёдор Иванович Шаляпин (1873–1938) – рус опера һәм камера җырчысы, Зур һәм Мариинский театрлары солисты.

[4] Эдвард Хагеруп Григ (1843–1907) – күренекле Норвегия композиторы, пианисты, дирижеры.

күңеленә дә иңә. Дүрт-биш яшьлек малайлар үзләреннән кечкенәләрне кыерсытырга гадәтләнәләр, кызларның чәчен тарталар, нәниләр ясаган ком тауларын ишәләр, уенчыкларын тартып алып ваталар, кыралар. Тудыру, ясау, кору, төзү белән янәшә үк кешедә җимерү, вату, җиңү инстинкты да туа. Җиде-сигездә малайлар танк рәсеме ясый, зәңгәр канатлы, кызыл йолдызлы самолётлар белән дәфтәр битләрен тутыра. Бу кинолардан күреп, китаплардан укып кына түгел, кеше җаны Җиңү дәгъвалый, өстенлеген расларга омтыла. Өстенлекне алга куеп яши башлау да – Мәңгелеккә омтылу.

Баланың кайсы инстинкты алгарак китәр, анысы тирәяккa, бала яшәгән мохиткә бәйләнгән.

Хәреф таныганчы ук күп балалар исемнәрен язарга өйрәнәләр. Хәрефләрне кирле-мырлы куя-куя, тигезле-тигезсез юлга үз исемен сыйдыра бала һәм шуннан китә! Өй стенасына, урам тузанына, акшарланган мич кабыргасына, үсеп-күкрәп утырган агач кайрыларына, кулына ни эләксә, шуның белән исемен беркетә. Әле ул бу дөньядан кайчан да булса китәсен уйламый, әмма уянган күңел үз вазифасын төп-төгәл үти – Кеше, Адәм баласы, Мәңгелеккә омтылганын белми дә кала. Әлегә бу омтылыш бердәнбер һәм дөрес чагылыш таба – кайда да исемен беркетү юлы белән кеше үзенең барлыгын раслап, гомерен озайтырга тырыша. Шәһәр йортларына күз салыгыз, бөтен йортларда диярлек «Фәрит + Әминә = мәхәббәт» дип сырланган. Бу ике җанның Мәңгелеккә беренче талпынуы, чөнки Фәрит – Әминәсез, Әминә Фәритсез токымын дәвам итә алмаячак. Бала җаннары да инде бер-берсен эзлиләр, күңел монда да акыллы киңәшен бирә: «Уян, эзлә, тап, кушыл!» Әлегә әнә шулай, стеналарга исемеңне янәшә куеп та кушылырга мөмкин. Астарак нык, эре-эре хәрефләр белән «Булат – дурак!» дип язып куелган. Бу да Мәңгелеккә омтылуның бер төре. Моны, әлбәттә, кыз бала язган. Ул: «Әгәр син мине вакытында эзләп тапмасаң, минем белән булмасаң, мине иш итеп нәсел-токымыбызны калдырмасаң, син – юләр!» Ямьсез яңгыраган ике сүзнең асылында нинди мәгънә һәм алдан күрүчәнлек ята.

Пәке очы белән исемнәрен теләсә кая сендергән егет-җиләннәргә без ләгънәт укыйбыз, «Чаян» журналы андый-

ларны әледән-әле «пешекләп» тора, әмма бу ярым кыргыйлыкның нигезендә яшәү омтылышы, Мәңгелеккә ашкыну яшерелгән.

Кавказ, Кырым тауларында йөргәндә, мин биек-биек текә таш кыяларның маңгаена майлы буяулар белән, ат боты-ат боты хәрефләр белән язылган, әллә кайлардан кычкырып торган исемнәрне күреп шаккатам, шунда менеп җитәргә кирәк бит, буявын юнәтергә кирәк (әле монда идән буярга табалмыйча тинтерисең!), шунда бауга бәйләнеп асылынып торып кыяга исемеңне теркәргә кирәк. Бүтәнчә мөнү юлы юк! Күпме мәшәкать чигеп, ничаклы интегеп, акча түгеп йөргән ул Паша-Машалар, Петя-Митяларны да әнә шул Мәңгелеккә йөз тоту дәртләндергән. Алар шушы мизгелдә үз бурычлары үтәлде дип сөенгәннәр һәм күмәк бәхетне татыганнар. «Күрегез, безнең исемнәр таш кыяның күкрәгендә калды. Мәңгелеккә!»

Дөрес, буяулы кулларын тау чирәменә сөртә-сөртә чистарынганда, буяу эзләрен юарга керосин эзләп чапканда, алар мондый сүзләрне әйтмәгәннәрдер, әмма Күңел төпкелендә канәгатьләнү, сөенеч һәм горурлык уянмый калмагандыр...

Мәңгелеккә омтылыш нәтиҗәсендә адәм баласының күңеленә Мәхәббәт иңә, егет белән кыз бер-берсен эзләп табалар. Ир белән Хатын дигән югары дәрәҗәне алалар. Мәхәббәт җимеше булып, Мәңгелекнең иң ышанычлы дәлиле — Бала туа...

Бала...

Балага мәхәббәт... Аннан да бөек, аннан да татлы, аннан да рәхәт хис бармы бу дөньяда? Белмим, юктыр. Бала — кеше яшәешенең якты, тирән мәгънәсе...

Гади генә яшәгән, гади яшәргә әзерләнгән татар егете Габдулла күңелендә дәһшәтле нәфрәт беренче канлы сугышлардан соң ук уянды. Дошманга нәфрәт, үч алу хисе, дошманны күралмау — Мәңгелеккә омтылышның бер тармагы ул, әле ышанучан гади акылы белән сугышның һәлакәт китерүенә йомгак ясап бирә алмаса да, Габдулла сугышның бик күп ир-атларның, адәм улларының Мәңгелеккә барыр юлларын вакытсыз кисә торган афәт, гайре табигый хәл икәнлеген Күңеленең бөтен дулкыннары белән тойды. Туган ил,

Идел-йорт, Туган халкың Мәңгелек икән, фашист-дәҗҗал әнә шуларны кырырга, көл итәргә килә. Синең нәсел-нәсәбеңнең, гомер агачыңның тамырына балта чабарга килә.

Мәңгелеккә омтылышы көчле булган егетнең!

Караңгы төн, өстә авыр шинель, аякта калын табанлы кирза итек, кулда автомат, аркада капчык, дөм кара елга өстендә көймә койрыгына снаряд төшеп ярылгач, ул салкын суга чалкан барып төште, каушаудан мие томаланды, судан калкынды һәм дәү генә такта кисәгенең нәкъ уң кул якта булырга тиешлеген үзен Мәңгелеккә турылаган Күңел күзе белән күрде. Автоматын сул иңенә күчергән иде, уң кулы буш иде һәм шул кул такта башына чытырдап ябышты...

Күңел күзе...

Нинди өметле, якты сүз тапкан татар халкы. «Күңел күзең күрмәсә, маңгай күзең – ботак тишеге» дигән. Ә, маңгай күзе дә нинди үткен, нинди җитез, ә Күңел күзе янында ул гап-гади ботак тишеге икән! Күңел күзе – Мәңгелеккә омтылыш күзе ул.

Шинель, манма су булып, аны аска сөйрәде, төпкә тартты, як-якта снарядлар ярыла, елга кайный, кемнәрдер илерепилереп дөнья белән саубуллашалар, кайда уң, кайда сул – белерлек түгел, су котырынып бөтерелә, йолка, батыра, ә Габдулланың Күңел күзе туры юл сайлый алды, ул, берәр потлы итекләрен чак сөйрәп, ярга чыгып егылды...

Әллә ничә снаряд берьюлы тиеп танкны бөтен яктан ут камаганда, иптәшләре үлеп калганда, дөрләп янган килеш ул танктан чыга алды. «Күзең ничек янып пешмәде икән?» – дип шаккатты соңыннан врачлар, таң калды...

## *Күз...*

Малай чакта дустым Әтәч Ибан белән, мунча ишеген мәрә[1] ясап, бакыр көпшәле наганга шырпы күкерте һәм дары тутырып, «атыш ярышлары» үткәргән идек. Ибанның күз астына наган көпшәсенең кыйпылчыгы китереп бәргән иде. «Күзне фәрештәләр саклый», – дип аңлатканнар иде әпчи карчыклар бу хикмәтле хәлне. Фәрештәләр түгел, маңгай кү-

[1] Мәрә (*диал.*) – мишень.

зен дә Күңел күзе саклый. Танкны ничек ача алганын, ничек чыкканын Габдулла белми, хәтерләми, иссез-өнсез иде ул хәтәр мизгелдә егетебез, әмма бу мизгелдә дә аның белән Күңеле җитәкчелек иткән, тимер чыдамыйча эреп акканда, корыч кайнаганда, ул аны өскә чыгарга өндәгән, көч биргән, башня капкачының снаряд шартлавыннан ачык икәнен белдергән, сул җиңе белән күзен томаларга боерган, чыгуга атып екмасыннар өчен, чылбыр тирәсенә елышырга кушкан. Дөрләп янган гәүдәне, шунда ук калкытып, кар тулы тирән канауга илтеп ташлаган. Кеше, логик акылы белән боларның берсен дә аңламый, аңлата да алмый, гайре табигый очракларда кеше ихтыярына Күңел тулаем хуҗа булып ала, Мәңгелеккә ифрат тугры Күңел адәм балаларын бик күп бәлаләрдән коткара, бәла-казалардан йолып ала.

Сөләйман бабайның Капка турындагы уйларын хәтерлисезме? Аның Күңеле дә шушы капкадан озакламый чыгып китәсен сизенә иде. Ул чыгып китә икән, кемдер кайтып керергә дә тиеш. Шулай булмаганда, изге Мәңгелек чылбыр өзелә. Әгәр берәүнең дә кайтып керәсенә ышанмаса, ул яңа Капка турында уйлый алыр идемени? Бәлки, Разиясы акылга килер, көтмәгәндә авылга кайтыр. Сөләйманның күзе мәңгегә йомылганда, якты дөньяга, Югары авыл тирәләренә, Изге чишмәгә, Йомры ташка аның акылы белән, аның Күңел яктысы белән карар...

Зөләйха әби ак маен язып бетерде дә, ялгышып, аны сары май итеп эретеп алды. Гаҗәпләнде, үзен «тинтәк» дип сүкте, асылда, монда да искитәрлек эш юк иде. Зөләйха да иртәгәге көне белән яши иде, тормышы бүген белән чикләнмәс, иртәгә дә көн булыр, шул иртәгә аны да иплəп кенә Мәңгелеккә илтер дип ышана иде. Солы коймагы пешереп, сары май белән мул майлап, Габдулласын сыйлыйсы килә иде аның. Акылы белән ул моны күз алдына да китерә алмады, әмма Күңел... Күңел түренә мәңге китмәскә урнашкан Габдулла әнә өстәл янына утырган да майга манчый-манчый коймак ашап утыра...

Сөләйман карт җиз төймәләр белән бизәлгән йөгәнен берәүгә дә бирми, һаман саклый! Ат чабышларына катнаша алмады Сөләйман, чабышкы атлары булмады, ул һаман үзе

башкара алмаганнарны да Габдулласы үтәр, башкарып чыгар, ул өметләнгәннәрне тормышка ашырыр, дип көтә иде...

Әдипләр күбрәк аналарның балага булган мәхәббәте хакында язалар, әти кешеләр, янәсе, кырыс була, алар дөнья гаменә чумып яшәп, гаиләдә тәрбия эшләренә катнашмыйлар, бөтен авырлык аналар җилкәсенә төшә, дип раслыйлар. Ә алаймы икән? Алаймы?.. Буш күңелләр була, таш күңелләр очрый, ләкин кайнар җанлы аталарның балага мәхәббәтен сөйли алырлык, аңлатырлык кодрәт тә, сүз дә юк... Сөләйман картның «олан, оланым!» дип калкып-ныгып килгән ак каенны назлаганын гына бер күрсәтергә иде сезгә!.. Сөләйман балаларының өчесен дә тигез күрде, керсез мәхәббәт белән яратты. Зөләйха моны белә иде, ул картын балаларны сөйгән өчен дә яратты бугай. Сөләйман аңа бермәлне: «Бар да булды, сиңайтәм, ачлык-ялангачлыкны да, бәхетне дә татыдык, бала сөеп кенә туеп булмады», – дигән иде...

Ил агасының оныкк көтә башлаган мизгеле җиткәнен белдерүче уй иде бу, олы уй, чын уй, матур уй иде.

Нишләсен Зөләйха, ни әйтсен дә ни дип картының күңелен юатсын. Килен булып төшкәч, шактый вакыт бәбәйгә уза алмады, бәбәй арты бәбәй ташыр чагы кысыр үтте, дип әйтергә ярый, тапканнарының да икесе дөрес булмады, өченчесе, оланнары, канлы кырларда югалып калды...

# Аяз Гыйләҗев хатлары

## «Хат – сәнгатьнең бер төре ул» (А. Гыйләҗев)

Хатларны саклау үтенече белән әдип якыннарына еш мөрәҗәгать иткән, ләкин, төрле сәбәпләр аркасында, күп кенә язмалар юкка чыккан. Ә инде сакланып калганнары безгә язучының тәрҗемәи хәлен өйрәнергә, шул чорга хас булган сәяси-иҗтимагый вакыйгалар турында фикер тупларга ярдәм итә.

«Хатларның бу төргәгендә лагерьдан әти-әниләргә, туганнарга, соңра Нәкыягә атап язылганнары сакланган. Карабас, Актас, Волынка, Караганда-Фёдоровка лагерьларыннан өйгә бик күп хатлар салсам да, күпчелеге озын юлларда гаип булганнар. Исән калганнарын Нәкыягә машинкада ике нөсхә бастыртып, икесен дә китап итеп төпләтеп куйган идем. (Шулардан күрмәкче, бөтен хатларны да китап итеп куярга ниятләдем!) Алары саклана. Лагерьдан килеп ирешкән хатларны әни лапас өрлекләре астына, төрле җирләргә кыстырып саклаган. Гәрчә... алар арасында куркырлыклары юк. Әти-әнине жәлләп, мин үз тормышымны һәрчак җиңеләйтеп, матурлап язганмын икән. Алай да әти-әнинең күпме хәсрәт кичергәнен үз балаларым үсеп җиткәч, Рәшат улым солдат хезмәтенә киткәч кенә аңладым. Соңга калып өлгерә аң, соңарып!..»[1] – дип яза А. Гыйләҗев үзенең искәрмәсендә.

Үзе исән чакта ук әдип тормыш иптәше белән хатларын тәртипкә китерү эшен башлаган. Бу эшнең сәбәбен ул менә ничек аңлата: «Хатларымның копияләрен алып калуымны ничек кабул итәрләр? Аңларлармы? Бу эшкә театр режиссёрлары белән аралаша вә языша башлагач керештем шикелле.

[1] А. Гыйләҗевнең шәхси архивы: лагерьдан язылган хатлар турында (1989, 7 гыйнвар).

Алар яза, син язасың, җавапларында нинди фикерләр, тәкъдимнәр, яңалыклар киткәнен хәтердә тотып бетереп булмый. Шуннан гадәтләнеп киттем дә, мә сиңа! язарга керештем.

Элгәре кәгазьнең ике ягына да язганмын, кәгазь битләренең сыйфаты, размеры хакында уйлап та карамаганмын. Бу җәһәттән соңгы ел хатлары аерылып тора. Бу төпләмгә элеккеге томнарга кермичә калган, башта күзгә чалынмаган папкаларда посып яткан төрле ел хатлары керде. Төпләгәч, тагын бер күз йөгертеп чыгарга кирәк булыр әле!.. Өйгә, Нәкыягә язылган хатлар да арага керде. Бөтен хатлар да саклanган дип раслый алмыйм, исән калганнары да байтак икән болай үзе!..

Үзем өчен генә җыймадым, берәр заман, без яшәгән чор белән кызыксынучы җан табылса, әдәбиятка, театрга, яшәешкә кагылышлы байтак азык кергән бу томнарга!»[1]

Алга таба язучы шәхси хатларның тарихи әһәмияткә ия булуларын да ассызыклый. Алар аша шул чорның, шул заманның сулышын тоемларга мөмкин, ди: «Иптәшләр, хат алышкан дуслар, минем кебек үк, килгән-киткән хатларны саклыйлар микән? Юктыр... Юктыр... Хат бездә, татарда,– ыбыр-чыбыр, чүп-чар, укыйсың да ертып ыргытасың... Аннары хатларда дөреслек берчакта да төбе-тамыры белән язылмаган! Берчакта да! Сталин чоры шаукымы хатларда да калган, аның кара шаукымы бүген дә яши, дәвам итә...

Ә хат – сәнгатьнең бер төре ул, үзебез кичергән дәвернең характеристикасы. Менә байтак өлкән язучыларның сакланып калган хатлары журнал битләрендә күренеп-күренеп китте. Ләкин аларның берсендә дә мин тормыш чынлыгын, әдәбиятның асыл яшәешен күрмәдем. Безнең иптәшләрнең хатлары күп очракта уйларын, чынлыкны яшерергә тырышу гына булып чыккан... Ни кызганыч! Мактанмыйм, мин дә бик сирәк хатларда гына тәмам ачылып киткәнмен, фикерләрне үз дәрәҗәләрендәге сүзләр белән кәгазь битләренә беркеткәнмен...

Мин дә замана баласы булганмын шул!»[2]

---

[1] А. Гыйләҗевнең шәхси архивы: хатларның копияләрен алып калуның сәбәпләре турында (1989, 14 декабрь).

[2] А. Гыйләҗевнең шәхси архивы: хатлар турында уйлану (1989, 6 гыйнвар).

Озак вакыт язучының хатлары көндәлек язмалары вазыйфасын үти.

2001 елда, үзенең шәхси архивын системалаштырганда, А. Гыйләҗев болай дип яза: «Минем архивымда ун меңнәрчә хат саклана. Күпчелеге – үзем язган хатлар. Шулай булды. Гомерем буе машинкада язып яшәдем. Хатларның копияләрен алып калу бер дә кыен булмады. Каян килде бу гадәт миңа? Яраткан урыс язучысы А. Чеховның сайланма әсәрләре арасында хатлардан гына тупланган томнары да бар иде. Мин шул томнарны ясканып, яратып, үтә нык тәэсирләнеп укып чыктым. Һәм күңелемә бер уй сеңеп калды: хатлар, баксаң, кыйммәтле әдәби документ та була ала икән. Нәтиҗәдә, гомерем буе шушы кагыйдәгә тугрылык саклап яшәдем. Хатларымны уй-фикерләр белән ныгыттым: елныкын-елга аерым папка итеп туплап, төпләп җыя бардым. Ибраһим Салахов белән, Якуб Зәнкиев белән, яшьрәкләрдән Вахит Юнысов белән озак вакытлар тоташтан хатлаштык. Алардан килгән хатларны да бөртекләп, кадерләп саклыйм. Заманалар үзгәрә икән, хатлашкан кешеләрнең инде байтагысы бу дөньядан китеп барды. Мин язган хатларда аларның якты хатирәсе, кыйммәтле уй-фикерләре саклана. Үземнең янып-көюләрем дә, татар әдәбиятына булган кайнар мөнәсәбәтем дә газета-журнал редакциясендә эшләүче яшь каләмдәшләремә мәгълүм булды. Замандашларымның күбесе мин язганнарның байтагысын юк итә барды. Мин моның аянычлы мисалларын бик яхшы беләм. Минем чынлыгым, бар булганым – халкыма булган тирән мәхәббәтем, шул хатлар аша киләчәккә дә барып җитәр, дип ышанып яшим. Әгәр кем дә булса берәү бу гамәлләремдә хата фикер таба ала икән, аңа да үпкәләмим. Валлаһи, дип әйтәм, бу язмаларда әдәбият, сәнгать тарихы ниндидер бер дәрәҗәдә сакланып калыр»[1].

Г. К. Хөсәеновка язган хатында әдип үзенең хатларга булган карашын теркәп китә: «...Хатлар гомер бакыенда минем төп эшемнең бер җитди өлеше булды. Әсәрләргә сыймаган, әсәрләрдә әйтергә кыймаган уй-фикерләремне хатларыма

[1] А. М. Гыйләҗевнең шәхси архивыннан.

багышлап бушана идем бит»[1]. 1980 еллардан башлап бу вазыйфаны язучының көндәлекләре үти башлый: «Миңа бушанырга, сердәшем машинкага карап, уйларның төрлесеннән котылып яшәргә кирәк. Көндәлекләр әнә шул миссияне үтиләр дә...»[2].

1992 елда А. Гыйләҗев махсус рәвештә хат алышуын киметә: «Туксан икедә хатларны нык киметтем, хисләрне бүлешерлек, уйларны уртак итәрлек, сер чишеп җиңеләйтерлек адәмнәр калмады. Уйларымны ялгызлар тыкрыгына алып кереп киттем дә караңгы күлгә – «көндәлекләргә» яшердем»[3].

Язучы хатлары автор орфографиясен һәм синтаксис үзенчәлекләрен саклап бастырыла.

*Миләүшә Хәбетдинова*

---

[1] А. М. Гыйләҗевнең шәхси архивыннан: А. М. Гыйләҗевнең Г. К. Хөсәеновка язылган хатыннан. 22 декабрь, 1994 ел, Казан.

[2] А. М. Гыйләҗевнең шәхси архивыннан: Көндәлек. 31 март, иртәнчәк, 1995 ел.

[3] А. М. Гыйләҗевнең шәхси архивыннан: «1992» папкасына язучының кереш сүзе, 1993 ел.

Н. ГЫЙМАДИЕВАГА
13 ноябрь, 1953 ел

## Тапшырылмаган хат

Сөекле дус!

Ябылмыйча калган тәрәзәңнән уйга талган моңсу бакчаның, вакытсыз һәм теләмичә намусын югалткан догачы кызның шыпырт кына Аллага ялварганы кебек, көзге лептердәвен тыңла. Тыңла син көзге сары яфракларның пошаманлы үксү авазын! Гөнаһлы дәрт белән аекмас мәс булган кешеләргә көзге үлгән аллеялар гомерлекнең мәңге булмавын, давыллы яз артыннан талгын җәйнең һәм җәй артыннан сары парчалы кәфенгә төренгән көзнең килүен сөйлиләр. Тыңла әле! Тыңла! Әгәр теләсәң, ташландык аллеяларга сибелеп яткан кызыллы-сарылы яфрак еләмен таптап йөр дә йөр. Яфраклар сиңа, синең дә мәңгелек түгеллегеңне, синдәйләрнең бу яфраклы җир астына сансыз күмелүен сөйләрләр... Тик кызганыч, кешеләр буш зәвыклар белән мавыгалар, тән саталар, тәннәре таушалгач, җан саталар, көзге матурлыкның ялганчы коточыргыч эчтәлеген сизмичә көн үтә. Төннәр мәшәкатьле тынгысыз, парлы һәм исерткеч ашкынулар, буш үбешләр белән тулган... Тән саталар, тәннәре таушалгач, җан саталар, көзге матурлыкның ялганчы, коточкыч эчтәлеген сизенмиләр... Уйлама! Гөнаһлы җир гөнаһлы кешеләрне генә тудыра, Аллалар, кешелекнең рухы тар вакытта, Грециядә Олимпия тауларында яшәгәннәр, анда урын беткәч, күккә күтәрелгәннәр. Ә хәзер кешеләрнең күңелләрендә дә Аллаларга урын калмаган. Почмакларда мул куелган тәреләр, алтын катыргылы тавратлар, бәрхет сумкалардагы җылан мөгезләре – Аллаларны гөнаһ баткагына чумдырган зәгыйфь кешеләрнең уңышсыз көчәнеше генә.

Гаделлекне эзләп көчәнмә, Норвегия балыкчысының хижинасы да, таулы дагестанлының саклясы да, инглиз банкирының вилласы да эреле-ваклы гаделлек белән, гөнаһлы эшләр белән мәж килә. Ябылмыйча калган тәрәзәдән сентябрь кояшы белән яктыртылган ак каенның җырын тыңла. Музыка – кешенең пычрак комсызлыгы буйсындыра алмаган

бердәнбер илаһи зат. Кеше үтерүчеләр дә, затсыз талаучылар да, шәфкатьсез көчләүчеләр дә – музыка алдында коллар, буйсынучылар. Музыка табигатьнең гүзәл чагылышларында, сихерле күренешләрендә туа. Кешенең миендә, кешенең комсыз теләкләренә хезмәткә туган музыка, ул сәнгать түгел – ул көлке. Көлке, сөекле дус, геморрой белән авыручы, газап чигүче бөршәйгән, күксәү фирка әһелләре музыканы да сатып алырга уйлыйлар, ләкин алар сатып ала алган композиторларның сыек аңнары юньсез мәгънәсезлек кенә тудыра.

Табигать! Син гүзәлсең, серлесең! Синең матурлыгың кешеләрне сокландыра, мәңгегә аларның күңелләрен били. Иренмә, кичке шәфәкъ баткан чакта елга аръягындагы болыннарга кара. Табигать үзенең барлыгын иң оста рәссамнәр кебек, тагын да гүзәлрәк, сокландыргыч итеп буяган. Ә кеше – варвар, бу гүзәллекне ерта, җирнең күкрәген канлы буразналар белән чуарлый, аның өстенә, үрмәкүч шакшы пәрәвез сарган кебек, аркылы-торкылы чыбыклар суза. Мина, кеше кулы тигән җирдә, кеше белән табигатьнең чиксез дуслыгы – кеше бәхете күмелгән кебек. Телефон баганалары бу урында чиксез зур дәһшәтле хачлар булып тырпаеп торалар, чыбыклар җир астына вакытсыз күмелгән кеше бәхетенең ыңгырашуын ишетеп, чиксез пошаманлыкта әрнеп җылыйлар. Ә баганалардан, кешене мәсхәрәләгән кебек, баш сөяге сурәте тырпаеп карый! Кайбер вәхшиләр бу – кешелекне мәсхәрәләгән тамгаларны маңгайларына тагып: «Без халыкны коткарабыз, без аларның сакчысы!» – дип кәперәеп йөрделәр. Юк, болар кешеләр түгел, кешеләрнең шәйтан юнәлткән яктылыкта чагылган шыксыз күләгәләре генә. Болар – табигатьнең дусты булган гүзәл кешеләрнең тупас пародияләре. Әле аннан, әле моннан ниндидер алама килмешәкләр килеп чыгалар да, «Без һәм халык – бу берлек!» дип кычкыралар. Бичара халык эш белән, авыр хезмәт белән мәшгуль, күп вакытта ул бу бушбугазларның асылына төшенеп тә җитмичә, эш белән изелеп, бу тинтәкләрнең бимазалы «дуслыгыннан» гаҗиз булып, мескен башын ия.

Юк! Кеше ул – табигать баласы, ул табигатьтән аерылса – ятим! Аны кагалар, сугалар – ул үксез, ач та, ялангач та. Ул бай һәм татлы сөтле әнисе белән бергә булганда гына көчле!..

Сөекле дус! Сөекле дус!..

Ябылмыйча калган тәрәзәдән догалы авазлар белән кичке җил кереп, синең талган йөзеңне иркәләсә, мине уйла, уйла ерак далаларны һәм бәхетсез җир улларын! Кычкырсам да, ишетмәссең, җирнең өсте гүләп тора: атом бомбалары шартлый, корал эшләүче заводлар үкерәләр, ятимнәр, толлар һәм сугыш гарипләре әрнүле үпкәләү авазлары белән гөрлиләр, Себернең буранлы юллары буйлап чылбыр моңы эленеп тора... Минем зәгыйфь сөю тавышым боздай җансыз казах далаларында өшеп үлә. Моңаеп калган кичке җил, сихерле шәфәкъ батканда җирнең корбан сорап улавын җиңеп, сиңа минем мәхәббәт җырымны илтер!

«Казанда яз!» дигән пьеса яза башлаган идем. Көч юк, чөнки Казанда әле яз юк, ул ерак, язны сагынудан туган куанычсыз сагыш кына бар.

Сөекле дус!

Юатма! Кирәкми! Мин акрын гына, кышкы кына кебек сүнәм, сулам. Төнге гөл үзенең матурлыгын төнлә генә күрсәткән кебек; кара көннәрдә мин үземнең көчемнең җитлегүен сизәм. Тик миңа күз атып игътибарга алучы гына юк! Үтенергә? Кемнәрдән? Күпме көннәр вөҗдан газабы белән газапланам... Тыңла! Тыңла кичке җилне!

Булачак атаклы ДРАМАТУРГ[1].

Н. ГЫЙМАДИЕВАГА

26 февраль, 1954 ел. Актас. Караганда

Бүген минем ял көнем. Көн җылы. Түбәләрдән чырылдап су ага. Язгы хәрәкәт тә, шау-шу да, күңелле ыгы-зыгы да ишетелми. Тик менә бу, бертуктаусыз тамып торган тонык су

[1] 1953 ел, 13 ноябрь. Аяз бит минем туган көнемне бөтенләй белми. Без әле хатлар алышмыйбыз. 1954 елның декабреннән генә хат яза башлады ич ул миңа. Ә алай да «язмыш» аның колагына пышылдый торган. Бу хатны яңадан да миңа дип атап күчереп, «Әминә! Бу «Тапшырылмаган хат»ны укыгыз да Нәкыягә бирегез. Килештекме? 27 март, 1955 ел, якшәмбе, Караганда – Федоровка» дип тамгалап, өстәмәләр дә кертеп җибәргән.– *Н. Гыйләҗева искәрмәсе*.

тамчылары гына кырык... (кыя?мы – аңлап булмый...– *М.Х.*) куркып дерелдәп торган, өшәнгән кешеләрнең күңелләрен җебетеп җибәрделәр. Гүя, шифер белән ябылган түбә өстендәге юка ак кар катлавы эреп таммый, түбә астындагы бәхетсезләрнең кыш буе җыйналып килгән, кайдадыр шунда тузанлы почмакларда кысылып торган аһ-зарлары, сагышлары, кайгылары кояшның юмарт иркәләве астында йомшарып китеп, чыдый алмыйча тулыгып ташый иде. Хәсрәт сеңеп ташка әйләнгән, иркә сүзеннән, җылы аналар игътибарыннан, йомшак хатыннар назыннан, сабыйларның татлы үбешләреннән мәхрүм булган ирләр, уллар, аталар язның бөдрә җиле иркәләвенә түзә алмыйча, үкереп, әрнеп җылыйлар. Бу бәндәләр җырлаганда һәм җылаганда гына кешеләргә охшыйлар. Бу – җинаятьчеләр дөньясы. Бер тиенлек файдасыз сохари өчен илен саткан илсатарлар да, аңгыра һәм тупас үтерүчеләр дә, мал белән түгел, җан белән сәүдә иткән фахишләр дә, алла исемен калкан итеп мал талаучы оятсызлар да, эше юктан эш булсын дип лыгырдаучылар да, канлы театрларның зур сәхнәләрендә сүзсез рольләрне башкарган тыйнаклар да бар биредә. Язмыш бер кешене дә талымлап тормаган, үзенең катылыгын юмарт итеп өләшеп биргән. Тирә-юньдә – яз. Биек коймалар артында:

Счастье...
Мы стальными штыками оградим! –

дип җырлап узучы сакчылар да җырга шатланалар ахрысы, тавышлары ныграк, яңгырабрак ишетелә. Кешеләрнең күңелләрен болгандырырлык ачы бөре исләре дә, карап туймаслык йомшак нәфис яз бәрмәнчекләре дә юк биредә. Язның һәр елны калдырган хатирәләре генә уяналар, эзсез үтмәгән яшьлекнең давыллы истәлекләре генә бүген күңелдә өермә ясый. Куллар ирексездән ручка алалар. «Мәрхәмәтле кешеләр» циклыннан беренче хикәя туа:

## Исемсез

*(Новелла)*

Ул кичләрен ярым караңгы салкын коридорда йөреп үткәрә. Шыксыз гәүдәсен бөгеп, үкчәләре кубып беткән иске

итекләрен шыпылдатып, бер максатсыз әрле-бирле йөренә. Мич алдындагы чүп өемнәрен актарып, тәмәке төпчекләре җыя. Юеш тәмәке бөртекләрен ярылып беткән, каешланган учларына салганда, муенын кыегайтып, рәхәтләнеп китә ул. Сары калын кәгазьгә ут кабызып, ачы, зәһәр төтенне әрәм-шәрәм итмичә, йотлыгып, үпкәләренә тарта. Ул беркемгә дә комачауламый, аның барлыгы да беленми, саргайган плакатларга, буяулары уңган панельләргә, тузан белән капланган зәгыйфь лампочкаларга ничек күнеккән булсалар, аңа да шулай күнеккәннәр. Шулай да, җае килгәндә, аны һәркем кимсетергә, үчекләргә ярата. Гүя ул, ишек тупсасы янындагы шакшы төкерек савыты кебек, усал язмыштан зәһәрләнгән, ерткычланган бу кешелексез бәндәләргә ачуларын чыгарырга, әрнүләрен түгәргә урын булып хезмәт итә иде. Зәһәр кешеләр өметсезлектә һәр тупас намуссызлыктан юаныч табалар. Үткән-барганнар әдәпсез генә аның чикмәнен тарталар, култык астыннан асылынып торган чүпрәк кисәкләренә ут төртәләр, ул күзләре белән йотыгып чүптә казынганда, аркасына тибәләр. Ул гөрселдәп авып китә. Канәгатьләнгән ачык авызларның рәхәтен китереп, башы белән «чык» иттереп мич капкачына бәрелә. Кемдер аның көеп, саргаеп беткән, тузанлы әлвән кагы төсле бүреген тибеп җибәрә. Бераздан ул уфылдап урыныннан тора, мүкәләп, кармаланып бүреген эзли, яңа ударларны буйсынучан тынлык белән көтеп, җыерчыклы нәзек муенын төрле якка боргалый.

Үз милләттәшләре аннан качалар. Үзенең кайчандыр булган картларча вакլыгы, мыгырдanулары белән аларны алҗытып бетергән. Хәзер ул айлар буе беркем белән дә сөйләшми. Үз хәсрәтләре хәттин ашып киткән гамьсез кешеләр аның хакында күптән онытканнар. Аңа исеме белән дә дәшмиләр. Карлыккан тупас бугазлардан ачулы «Әй! Син!» авазы атылып чыкканда, ул ялт итеп борылып карый. Беркем дә аның йөз формасын белми, аның белән берничә еллар бер бүлмәдә торган кешеләр дә аның борынының, күзләренең нинди икәнлеген әйтә алмас иде. Сирәк-мирәк очраклы гына аның исеме телгә кергәндә, кешеләрнең күз алдына бер мәлгә генә төкерек савыты, аның янындагы шундый ук пычрак, төссез, формасыз җан иясе килә. Ул чит илдән. Беркем белән дә баг-

ланышы юк. Һәркем тарафыннан онытылган бу кирәксез кешене үлем дә абайламаган. Шук кешеләр усал шаярганда: «Аңа күптән агач бушлат кияргә вакыт. Үлем аңа каршы чыккан, тик аймыл гына булганнар»,— дип явыз хихылдыйлар. Мин Лайошны (исеме шулай иде бу бәндәнең) яңа урынга күчеп килгәч тә күреп алдым. Кешеләрнең аңа булган карашлары миңа да бик тиз йокты. Чөнки җәмгыять биредә үзе раслаган фикерләр, нәтиҗәләр белән карышусыз килешергә мәҗбүр итә. Килешмәсәң, көчләп тага.

Мин башкалар кебек ачыктан-ачык Лайошны мыскыл итмәсәм дә, аны кеше итеп санаудан ерак тора идем. Әгәр ул кичке ашка соңга калса, аның шулпасын яшереп куялар, һәм мин дә, башкалар белән беррәттән, аның ватык рус телендә үтенеч сүзләре ясавыннан рәхәтләнеп көлә идем. Аның киеменә сеңгән җирәнгеч исләр бүлмәдәшләренең ачуына тагын да ныграк сәбәп була, аны сүгәләр, төртеп бүлмәдән куалар, һәм ул еш кына коридорда йокымсырый. Юка ишекләргә басып торган салкын һава тишек-тошыклардан бүселеп, өрелеп керә, ул, кунаклаган каз бәпкәсе кебек, муенын тагын да тырышыбрак керле якалары астына яшерә. Бу кеше шулай кырыс, сөйкемсез булып туган кебек. Аны кемнеңдер «балакаем, йомшагым минем» дип иркәләвен күз алдына китереп булмый.

Ике бригаданы берләштергәч, безгә еш кына бергә эшләргә туры килә иде. Ул иң ярдәмгә мохтаҗ, хәлсез, йокымсыраган кеше булса да, башкалардан яхшырак эшли. Биредә отбой чүкечләренең шау-шуы, компрессорларның усал үкерүе, пневматик бәргечләрнең бәрүе астында Лайош үзенең уйлары белән генә кала. Үзенең хезмәт ритмына сабыйларча ияреп, ул көнозын эшли, алсыз-ялсыз балчык төйи.

Кешеләр аның хезмәт сөюеннән усал файдаланалар. Һәркем аның белән парлап басарга тырыша, чөнки Лайош ике кеше өчен эшли, ялкауланган иптәшләренә әр сүзләре ташламый. Март башларында 12 метр тирәнлектә балчык базында утырганда, миңа искиткеч вакыйганы күзәтергә туры килде.

Аның белән миңа балчык ватарга куштылар. Буш вагоннар көткән арада, забойда кара-каршы утырабыз. Кинәт Ла-

йош башын җитез генә күтәрде, аның муены калтыранып китте. Мин беренче мәртәбә аның йөзен күрдем. Борын яфракларыннан башлап, ике җәя булып, кап-кара тирән чокырлар түбәнгә сузылганнар иде. Төссез, йон баскан чыраенда коточкыч хәсрәт, ачлык чагылдырып торган бу чокырлар – бу кешенең дәһшәтле, газаплы гомере турында сөйлиләр. Йөнтәс, тәртипсез чәбәләнгән эре бөртекле кашлары астына гаҗәеп күзләр посканнар. Гүя, бу – күзләр түгел, ә болганчык су тутырылган кечкенә савытлар, һәм бу суга «язмыш» дип аталган шаян рәссам аңлаешсыз буяулы пумалачыгын манып алган. Буяу, су өстендә, әллә зәңгәрсу, әллә соры булып, таралмыйча тора. Лайош минем усал түгел икәнлегемне белә һәм үзен шактый кыю тота. Аның тешсез авызы, ябык, аксыл иреннәре, кутырлы ияге, исән калган тешләренең юшкын белән капланган самавыр стенасы кебек калын, сары кунынктан гына торулары бу кешедән чирканып читкә борылырга мәҗбүр итә. Ул миңа зур авызын ерып, елмаерга азапланып карый. Битендәге ерганаклары тагын да аяусызрак булып тирәнәяләр. Мин аның сөйләшүне сагынуын, сөйләшергә теләвен сизеп алдым.

– Йә, йә, Лайош агай, – дип кычкырдым мин. Ул бияләйләрен салып ташлап, киң учларын бер-беренә сугып үз телендә миңа нидер кычкыра башлады. Ул үзенең әнисе телен сагынган иде булса кирәк, озаклап, миңа нидер сөйләде һәм минем берни дә аңламаганлыгымны белсә дә, берничә сүз әйткән саен, миннән русча «аңлыйсыңмы?» дип сорый иде.

Бәлки ул үзенең чиксез бәхетсез икәнен, үзенең хәсрәтен, кимсетелгән үгәй гәүдәсендә адәм җаны йөрткәнлеген сөйләгәндер. Ләкин боларны сөйләү аңа үз телендә җиңелрәк иде ахрысы. Җиңелрәк тә, рәхәтрәк тә... Кинәт бу утлы, сихерле чардашлар иленең кешесе башын артка ташлады, муенын кыегайтып кызганыч кыяфәткә керде, һәм үтә ягымлы, ниндидер кызганыч бер җырның агып чыгуын ишеттем. Гаҗәпләнеп тирә-якка күз салдым. Юк, Лайош җырлый. Ул төссез күзләрен хәрәкәтләндереп, калын, аксыл иреннәрен кыймылдата. Мин аңа «Йәле, йәле! Нинди дә булса чардашны», – дим. Ул миңа якынрак сыена, минем аны гадәттәгечә куып җибәрәсем килми. Ул, кулларын бутап, бозык рус те-

лендә сөйли: «Минем бик күптәннән опера тыңлаганым юк. Ай, күп эшләдем мин үз гомеремдә, ай күп! Хәзер аз эшләр идем. Минем бер кызым, бер улым үсеп җиттеләр. Ләкин хәзер мин монда!» Кинәт ул ачыргаланып күтәрелде һәм, кубардай бөтерелеп, көрәген күтәреп балчык төйи башлады. Сүзгә мавыгып, без буш вагон килеп җитүен күрми калганбыз. Моннан соң Лайош көн буе сөйләшмәде. Мин «җырла әле ни булса да» дип җөдәтсәм дә, ул ачылып китүеннән үзе дә уңайсызланган ахры, баш кагып, риза түгеллеген белдерә. Кич җитә.

Кинәт сүз китә. Яңа килгән «№лы» берәү фортепионада өйрәнергә тели, имеш, һәм кыска срокта өйрәтүче табылса, яхшы хак вәгъдә итә. Бу кыргый гадәтле, тар маңгайлы кешедән куркалар иде һәм өйрәтергә ирекледәр табылмады. Ә ул сөйгән кызына вәгъдә биреп өлгергән һәм март ахырына кадәр аны Шопенның «берәр нәрсәсе» белән шаккатырырга уйлый иде. Бу хәбәрләргә сак кына колак салып йөргән Лайош кичкә кырын җыйнала башлады, бик озаклап уфылдап юынды, иленнән бердәнбер истәлек булып, үз иленең герблы төймәләре белән бизәлгән иске чикмәнен киде. Һәм гадәтенчә чайкала-чайкала клубка китте.

Өйрәтүдән баш тартучы музыкантларга ачуы чыккан «№» клавиатурасы ачык фортепиано янында сүгенеп йөренә. Ишектән шыпырт кына кергән сәләмә күләгәгә ул җен ачулары чыгып карады. Лайош бусага янында аякларын алыштыргалап торды да кыюсыз тавыш белән: «Мин Будапешт консерваториясен алтын медаль белән тәмамладым!» – диде. «№» ватык рус сүзләренә төшенсә дә:

– Нигә килүеңне сөйлә! – дип мыгырдады. Лайош начальство белән сөйләшергә күнекмәгән иде, ул калтырап китте һәм кыйналудан куркып, чак көчләрен җыеп, үзенең дәрес бирергә теләвен әйтте. «№», җирәнеп, бу шыксыз күләгәгә карап торды. Йөзен чытты... Эш хакын тиз килештеләр: эш яхшы барса, һәр кичне бер котелок бәрәңге булачак.

Лайош чикмәнен салып почмакка ташлады һәм, сак кына атлап, фортепианога якын килде. Ялтыравыклы ак пластинкаларын күргәч, ирексездән, яргаланган бармакларына күз төшерде.

– Йә, йә! Күрсәт, – диде «№».

Лайош гүя аның тавышын ишетмәгәндәй күзен аска төбәде, ул җаны-тәне белән фортепианога ымсынган иде. Көчле авазлар көтмәгәндә аның эштән тупасланган бармаклары астыннан ургылып чыктылар, салкын зал үзенең ямьсез, шыксызлыгыннан айныгандай калтыранып китте, юылмаган сөремле сәхнәдәге салам карачкылар ярыктан өрелеп кергән әрсез җил белән шаярудан туктадылар. Залда хөкем сөргән күңелсезлек, ялангачлык акырын гына иңрәп үлә иде. Лайош катлаулы пьесаларны кабат-кабат йөгерек темп белән уйнады. «№,, аңына килеп, аның ябык иңбашына кулын салды. Лайош акрын гына аңа башын борды. Аның иреннәре калтырый, ябык бите буйлап бертуктаусыз күз яшьләре агалар...

– Җитәр! – диде «№», – җитәр, бүгенгә мин... бүген һични теләмим.

***

Таң белән ике барак арасында Лайошның үле гәүдәсен таптылар. Ул йомшак март карын кочаклап чалкан ята, ачылып киткән куеныннан чыгып килгән кояшның нурларына чагылып ялтыраган искиткеч кар бөртекләре арасына вак кына, кап-кара туңган бәрәңгеләр чәчелгән иде.

*1954 ел, 26 февраль, Караганда–Волынка*

## Ш. ГАЛИЕВКӘ

1962 ел, 27 ноябрь, Мәскәү

Шәүкәт[1]! Ни хәлләрдә ятасың, 34 яшьлек шагыйрь?

Мин синең өй адресыңны буташтырам, ахры, шуңа күрә бу хатымны Союзга атап язарга торам. Туган көнең белән котлап телеграмма җибәргән идек, алдың микән? Ярым шаярулы шук кына нәрсә иде ул. Башкортлар шукланырга яраталар бит алар.

[1] Шәүкәт Гали улы Һидиятуллин (1928–2011) – Татарстанның халык шагыйре (1995). ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1972), Г.-Х. Андерсен исемендәге халыкара Почётлы диплом иясе (1982).

Әйе, сиңа 34 яшь! Адәм баласына гомер аз да бирелгән соң! Әллә, син әйткәндәй, без бик соң өлгерәбезме? Шуңа күрә гомернең азлыгы аерата үкенечле тоеламы? Бәлки, аның шул азлыгында да матурлык, илаһилык бардыр? Кем белсен! Тиздән миңа 35 тула. Менә моны күп дисәң дә ярый. Ә 34 – тегеләй-болай, ярым-йорты.

Сиңа хат язарга дип күптән җыенып йөрим. Ләкин без, аерылганда, шактый төшенкелек белән саубуллашкан идек. Син алып кайткан теге хәбәр бер мәлгә генә мине аяктан егып торган иде. Шуңа күрә мин тиз генә синең белән сөйләшерлек хәлгә килә алмадым. Мәскәү тормышыннан сине куандырырлык хәбәр килеп чыкмасмы, синең арган-талган күңелеңә берәр шифалы тамчы тамыза алмаммы дип йөрдем. «Өч аршын җир»не тагын бер кат карап чыгып, бүген журналга[1] җибәрдем. Моннан элек тә Әхсәнгә[2] бер хат язган идем, бүген тагын бер-ике авыз сүз өстәп тыктым. Повесть әйбәт кенә чыккан кебек тоела. Укыган кешеләр ошаттылар. Нәҗип[3], Әнгам[4], Искәндәр[5]... Ләкин дөньяда моннан да куанычлырак бер хәбәр бар. Шәт, аны үзең дә ишеткәнсеңдер инде. «Новый мир»[6] журналының 11 нче санында А. Сол-

[1] «Совет әдәбияты» журналы турында сүз бара.

[2] Әхсән Фәтхелбаян улы Баянов (1927–2013) – татар әдибе, шагыйрь, прозаик һәм драматург, ТАССР атказанган сәнгать эшлеклесе (1988), Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1999), Татарстан Республикасының халык шагыйре (2004).

[3] Николай Васильевич Асанбаев (1921–2013) – башкорт язучысы, шагыйрь, драматург. БАССРның Салават Юлаев исемендәге премия лауреаты (1983).

[4] Әнгам Касыйм улы Атнабаев (1928–1999) – язучы, Башкортстанның халык шагыйре (1997). БАССРның (1977) һәм РСФСРның (1988) атказанган сәнгать эшлеклесе.

[5] Искәндәр Галиәскәр улы Гыйзәтуллин (1922–1976) – тәрҗемәче.

[6] Айлык әдәби журнал. 1925 елдан Мәскәүдә бастырыла.

женицын[1] дигән кешенең «Один день Ивана Денисовича»[2] дигән повесте басылган. Аның басылу тарихы да шактый поучительный икән. Редколлегия члennары бердәм рәвештә каршы булганнар. Әмма Твардовский[3] повестьны бастырып чыгару ягында булган һәм Хрущёв янына киткән. Өч сәгать сөйләшкәннәр алар. Бик үк төгәл булмаса да, билгеле булган мәгълүматлар бик кызыклы. Твардовский язучыларга ирек бирү, аларның иҗат канатларын киңәйтү хакында сүз алып барган. Дөрес булса, әдәбият әйберләренә цензураны бетереп, хәрби цензураны гына калдыруны шунда хәл иткәннәр, имеш, диләр. Сөйләшүнең беренче бәрәкәтле нәтиҗәсе булып, повесть басылып та чыкты. Мин аны кичә генә укып чыгу бәхетенә ирештем. Күземә яшьләр чыгып, дулкынланып укыдым... Менә ничек бит ул! Без әле «лагерьлар турында язарга рөхсәт итәрләрме» дип куркып, уйланып йөргән булабыз, руслар бастырып та чыгардылар. Бу – бик җитди адым. Без синең белән бу турыда икеләнмичә сөйләшеп йөри идек: «Безнең буын өстенә төшкән зур бурычларның берсе ул – шәхес культын ачып, актарып салу»,– дигән идек. Хәсән абыйның[4] артта, искереп, нәниләнеп калганын сизәсеңме инде? Ай, руслар алда баралар! Алардан һич тә читтә калырга ярамый хәзер. Синең төрле якка – юлга да, диңгезгә дә, артка да, алга да карап уйлануларың (кстати, син шундый бү-

[1] Александр Исаевич (Исаакиевич) Солженицын (1918–2008) – совет рус язучысы, драматург, публицист, шагыйрь, әдәбият өлкәсендә Нобель премиясе лауреаты (1970).

[2] А. Солженицынның исемен дөньяда яңгыраткан беренче басылган әсәре (әсәрнең беренче исеме – «Щ-854»).

[3] Александр Трифонович Твардовский (1910–1971) – рус совет язучысы, 1950–1954, 1958–1970 елларда «Новый мир» журналының баш редакторы. Сталин (1941, 1946, 1947) һәм Ленин (1961) премияләре лауреаты.

[4] Хәсән Фәхри улы Туфан (1900–1981) – шагыйрь. ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1966). «Аяз, төрмә-лагерьлар турында язуын үтенеп, Хәсән Туфанга еш мөрәҗәгать итә иде. Ә Хәсән абый аның бу омтылышын бервакытта да хупламады. Алар шул нигездә бер-берләреннән читләштеләр дә. Аязның: «Лагерьлар турында без язмасак, Хәсән абый, кем язар соң?» – дип дәшкәне хәтердә».– *Н. Гыйләҗева искәрмәсе*.

лекләр кертмисеңме? «Алга карап уйланулар», «Артка карап уйланулар»?) бик вакытлы дип исәплим мин.

Мәскәү рәхәт итеп, дулкынлап яши. Ул повесть сенсация булды. Журналны чират торып китапханәдә генә укыйлар, ди. Бөтен җирдә бар кеше шул хакта гына сөйләшә.

Булып узган пленумда Евтушенконың[1] теге шигыренә каршы чыгып маташу тенденциясе сизелгән икән. Әмма үзәктә ул шигырьне һәм аның юнәлешен бик нык куәтлиләр, ахры. Солженицын повестена багышланган мәкаләсендә Ермилов[2] булып Ермилов ул шигырьдән «наследники Сталина» дигән сүзләрне искә алып китә.

Безнең журнал, кирпеч калынлыгы опусларны басып ятучы Абдулла Гомәрләр[3], шул кирпечләрне тырышып-тырышып, еллар буе, суга мана-мана ялтыратып ятучы Ибраһим Газиләр[4] бүгенге көннең эре адымнары артыннан һич тә өлгерә алмыйлар. Шушы бер-ике ел эчендә никадәрле зур үзгәреш! Болай барса, безнең тормыш бик уңайга китәчәк. Минем моңа ышанычым арта.

Шуңа күрә аерым күңел төшенкелеген тудырган хәлләр алдында башыбызны имик әле! Син бик дөрес юлда торасың. Күп итеп, нык итеп эшләргә кирәк. Евтушенко «Страхи»[5] дигән шигырендә бик ачык итеп әйтте:

И когда я пишу эти строки
И порою невольно спешу,
То пишу их в единственном страхе,
Что не в полную силу пишу...

Әйе, Рәсәйдә «страхи умирают»...

---

[1] Евгений Александрович Евтушенко (Гангнус) (1932–2017) – рус совет шагыйре, прозаик, публицист, режиссёр, актёр.

[2] Владимир Владимирович Ермилов (1904–1965) – әдәбият галиме, тәнкыйтьче.

[3] Абдулла Закир улы Гомәров (1906–1974) – тәрҗемәче, журналист.

[4] Ибраһим Зарифулла улы Мингазиев (1907–1971) – язучы, җәмәгать эшлеклесе. ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1969).

[5] Евтушенко «Страхи» дигән шигырен Шостаковичның 13 нче симфония «Бабий Яр» си-бемоль минор ор. 113 өчен язган.

Повестьны җибәрдем... Бер-ике хикәямне карап чыгам да олы повестька тотынам. Соңгы вакыйгалар мине бик нык дәртләндерәләр. Элек уйлап куйган нәрсәләрне язарга вакыт җитте. Куркып тормаска кирәк. Сталин варислары акрын-акрын тәгәрәрләр, дип уйлыйм. Бездә дә, монда да, тегендә дә. Аларның көннәре санаулы.

Курсларда тормыш акрын үтә. Безнең Мәскәү чоры ахырына якынлаша. Кызганыч... Бәлки, кызганыч түгелдер дә ул? Бер мәртәбә ирекле булган, ирекнең татлы горурлыгын сизгән кешеләрне Казанның сөрсегән Матбугат йорты гына тышаулый алырмы соң? Һич юк!

Үзеңдә ниләр бар? «Камырша»ны[1] җибәр әле. Китап кибетләрендә бер дә йөргән юк. Русча китабыңны эзләрмен дип торам. Дусларга күп сәлам! Фәридә ханымга[2] да сәлам алып кайтырга онытма! Хат яз!

И. ГЫЙЗӘТУЛЛИНГА
12 декабрь, 1963 ел. Казан

Искәндәр![3]

Сәлам сиңа! Хатыңны бик көтә идем, бүген, ниһаять, алдым. Яшермим: мин, нигәдер, повесть[4] «Дружба народов»та[5] бармас, дип уйлыйм һәм синнән нинди генә җавап килсә дә – шуңа әзер. Тик мондый җавапны һич тә көтмәгән идем: алар мине тагын чакырырга уйлыйлармы? Әгәр шулай икән, иң элек мин аларның ни өчен чакырырга теләүләрен белергә телим. Кайсы төшен төзәтергә уйлыйлар алар? Нәрсәсе ошамады? Шулар булмыйча торып, Мәскәүгә барырга җыенмыйм. Әгәр алар миннән юк нәрсәләр сорап маташалар икән, аның өчен күт сыеклап йөрүдән мәгънә дә юк. Мин пьесаларның тәрҗемәләре белән «кәкере каен терәп» шактый тордым инде. Җитәр! Басылмый икән – басылмый! Минем сиңа әйткәнем дә бар инде, «Дружба»да басылуы – басылмау белән бер дәрәҗәдә. Инде болай: артык кәҗәләнәләр икән,

[1] Ш. Галиевнең балалар өчен шигырьләр җыентыгы (1962).

[2] Ш. Галиевнең хатыны.

[3] Искәндәр Галиәскәр улы Гыйзәтуллин (1922–1976).

[4] «Өч аршын җир» турында сүз бара.

[5] «Дружба народов» – әдәби журнал.

алардан алып, башка берәр җиргә биреп карамыйсыңмы? Читтән торып акыл өйрәтеп ята, дип көлемсерәмә, ни өчендер, башта ук «Новый мир»га бирәсем килгән иде. Бәлки, алар белән сөйләшеп карарсың? Дөрес, мин бик югарыга сикерергә уйлыйм, ләкин алардан отказ алсаң да күңеллерәк булыр иде! Ичмасам, атның асылыннан егылдым, дип юанып йөрер идең. Кем белә, бәлки, аларны кызыксындырып та куяр?.. Хәер, бу җәһәттән мин сиңа тулаем ышанам, һәм син үзең яхшырак беләсең, дип калам...

Мин Фаизовага[1] да ышанмыйм. Аннан хат та, хәбәр дә юк. Миңа тәрҗемәләр ягыннан да не везет. Белмим, нигә шулайдыр. Ул пьесаларны хуплап алганнарын күрсәң син! Күккә чөйделәр, ә берсе дә юньлегә чыкмады. Күпне көтеп, аздан коры калдым. Шуңа күрә, нинди җавап бирсәләр дә, түзгән баш түзсен инде, дип кенә яшәргә калды.

Казанда яңалыклар юк диярлек...

Кыш...

Салкын...

Сиңа журналны яздырдым. Квитанциясен җибәрәм. Кайтып, хатыңны карый алмадым, адрес шулай кирәк иде микән? 15 декабрьдә Уфага дип атап яза торган пьесаны, җитешеп, Нәҗипкә җибәрәм. Нәрсә диярләр.

Ярар, Искәндәр, сау булып тор. Рәшиттән[2] хатлар алам. Балык тотам, дип яза. Сәлам белән, АЯЗ.

И. ГЫЙЗӘТУЛЛИНГА

4 гыйнвар, 1964 ел, Казан

Искәндәр! Яңа елың котлы булсын, дустым!

Сәлам сиңа!

Кичә Евгения Львовна[3] мине телефонга чакырды. Озак кына сөйләштек. Ул повестьның ахырына беркадәр үзгәреш

[1] Разыя Фәизова – тәрҗемәче, «Литературная газета» хезмәткәре.

[2] Уфадан Мәскәүгә барып тәрҗемәчеләр курсында укыган Рәшит Зәйнуллин турында сүз бара.

[3] Евгения Львовна Усыскина – «Дружба народов» журналы хезмәткәре.

кертергә куша. Әгәр шул үзгәрешләрне 15 гыйнварга кадәр тәрҗемә итеп, өстәлемә китереп салсагыз, повесть 3 нче номерга керә, ди. Бүген 4 гыйнвар... Иртәгә якшәмбе. Мин 4 бүлекне беркадәр карап чыгып, 6да иртән сиңа авиапочта белән салам. Әгәр син дә сәламәт һәм тыныч булып, тиз арада караштырып эшне тапшыра алсаң иде! Аның тизрәк чыгуы икебез өчен дә саф файда гына ич! Мин 6 сыннан да калдырмам, дип ышанам. Иртәгә үк җибәрә идем, бүген начар йокладым, башым авыртып уяндым, эш тотасы килми... Ичмасам, повесть тизрәк басылып чыксын иде. Мондагы кыекмыек сүзләргә азрак чик куелыр иде, дип өметләнәм. Югыйсә, партиянең өлкә конференциясендә дә телгә алып, аны тәнкыйтьләп азапландылар ич! Аннары син «Зәй энҗеләре»н укып чык әле. Фәизованың тәкъдиме синең төшеңә генә кермәгәндер бит? Миңа бер хәбәр дә юк. Ул, мөгаен, повестьның соңгы өлешен ошатмагандыр. Гәрчә, укучылар «соңгы өлеше шәбрәк» диләр. Нихәлләрең бар? Синнән күптән хат алган юк. Ә минем күңел синнән хат һаман көтеп кенә тора. Иренмә әле син. Ары-бире килүеңне дә хәбәр иткәләп тор. Мин яңа пьеса тәмамладым да шуның белән изаланып йөри идем. Уфада һәм Әлмәттә куярлар, дип өметләнәм.

Менә шулай. Миннән тәрҗемәне көт. Сәлам белән, АЯЗ.

## ӘМИРХАН ЕНИКИГӘ[1]

14 май, 1964 ел, Урта Баграж

Кадерле Әмирхан абый!

1959 елның көзендә, «Чаян» журналына редактор итеп, надан һәм кара фикерле Сабир Бәхтияровны[2] җибәрделәр. Без, Шәүкәт[3] белән, аның киләсен белеп, бу ялгыш карарны ничек булса да үзгәртү нияте белән шактый тырышып йөргән идек. Ләкин эшебез барып чыкмады. Бәхтияров килү белән

---

[1] А. Гыйләҗевнең А. Еникигә язган хаты «Сайланма әсәрләр»нең 2 нче томына кертелгән (Казан: Татар. кит. нәшр., 2014, 453–456 б.)

[2] Сабир Сәлмән улы Бәхтияров (1913–2003) (псевдонимнары – Бухаров, Борисов, Бельский).

[3] Шәүкәт Гали улы Һидиятуллин (1928–2011).

безгә ташланды. Һәм мин аның белән бик тиз бәхәскә кердем. Ул миңа җәза уйлап тапты һәм Апас районына командировкага җибәрде. «Положительный фельетон» язарга кушты. Бүгенге көнгә кадәр минем «положительный фельетон»ның нинди булганын белгәнем юк. Әмма ул вакытта «ярар» дип әйттем. Башымны иеп юлга чыктым. Нишлисең, ул чагында минем урыным бик ныксыз, союзга член итеп алынмаган, фатир юк, акча юк һ.б.

Мең бәла белән Урта Балтай авылына барып төштем. Көз белән кыш бер-берсенә баш бирмичә тартышалар иде. Урамнар ерып чыга алмаслык саз, һава юеш, шыксыз иде. Шул авылда, чиста һәм ягымлы татар апасының өендә, көзге ямьсез кичләрнең берсендә минем кулга сезнең сайланмалар килеп эләкте. Хуҗа апаның тугызынчы класста укый торган кызы китапханәдән алып кайткан икән. Китапны мин аңардан сорап тордым һәм бик бирелеп укып та чыктым.

Фатирсызлык, вәгъдәсез Афзал Шамовлар[1], заманның ловкачлары Сабир Бәхтияровлар, урамнардагы ерып чыга алмаслык саз-пычраклар, миңа кушылган эшнең мәгънәсезлеге һәм өметсезлеге – бар да онытылды ул кичне. Китапны бер кичтә укып чыга алмадым мин. Икенчесендә дә, өченчесендә дә ул минем белән булды. Шунда, көчәнеп-көчәнеп язып маташкан фельетонны бер якка ыргытып, сезгә хат яза башлаган идем мин. Сезнең белән әнә шул кояш исе килеп торган чиста татар өендә очрашуның үзем өчен ифрат дәрәҗәдә сөенечле, рәхәт, куанычлы һәм файдалы булуын әйтергә теләгән идем мин. Тик нигәдер хатым тәмам кылынмады... Әллә безнең араларның әле шактый ераклыгы минем телемне бәйләде. Минем исә ул китапны укыганнан соң, тик чын күңелдән генә сөйләшәсем килә иде. Бигрәк тә, «Без дә сабан туен күрдек»тән соң... (Мин исемен бутамыйм микән?) Әле дә ярый җирдә яхшы кешеләр бар һәм алар үзләренең яхшылыкларын юмарт итеп башкаларга өләшеп бирә алалар, яраткан китапларың булмаса, заманның кара минутларында кемгә барып башыңны салыр идең, дип уйлаган идем мин ул чакта...

[1] Афзал Шиһабетдин улы Шамов (1901–1990) – язучы, җәмәгать эшлеклесе.

Хәзер, хат янымда булмагач, тәгаен генәниләр язуымны хәтерләмим, тик әнә шул авылда сезнең белән бергә үткәргән көзге кичләр биргән тәэсир бүгенге көнгә кадәр җуелмады, кеше һәм гражданин буларак, художник буларак, мин шул кичтә сезне күрдем сыман. Күңелем сезне олылау хисләре белән мөлдерәмә тулы иде. Әгәр мин хатымны «Әмирхан абый» дип башласам, сез минем тавышымны түбәнчелек, сезне олылау һәм ярату аһәңнәре ишетергә тиеш идегез...

Тик без барыбыз да заман балалары шул, игътибарлы була ук белмибез. Хатны әллә кайчан җибәрәсе калган. Һәм менә бүгенге хат ул чагында беренчесе генә булмас, икенчесе, бәлки илленчесе булган булыр иде...

Яшермим, яшәгән саен дуслар азаялар. Кешеләр арасындагы дуслар гына түгел, китаплар арасындагы дуслар да. Минем үзем өчен әдәби әсәрләрдә уңай һәм кире геройлар булган кебек, язучылар рәтендә дә уңай һәм кире авторларым бар. Мин һәрвакыт әсәрнең иң төп герое аның авторы дип саныйм. Мәсәлән, мин Солженицынны герой дип саныйм. Антуан де Сент-Экзюпери[1] дә, Эрих М. Ремарк[2] та – минем өчен шулай ук геройлар. Бәлки, бу яхшы ук түгелдер, әмма татар әдәбиятында, үземне авызландырган, аякка бастырган әдәбиятта «аһ» дип сокланып укыган әсәрләр азайганнан-азая баралар. Уңай һәм кире геройлар бик күп, уңай автор-геройлар юк дәрәҗәсендә...

Былтыр җәйге ял вакытында авылда, үз әтиемнең өендә еллык «Азат хатын» журналларын актарганда, мин сезнең «Рәшә»дән[3] өзек укыган идем. Әнә шул өзек тә (яшермим, минемчә, повестьның иң әсәрләндерә торган, югары мастерлык, кабатланмас талант көче белән язылган юллары басылган иде журналда, тик боларны мин соңыннан гына белдем) миндә гаять зур кузгалыш уятты. Зөфәр булып Зөфәрне дә әсәрләндерерлек, хәтта берникадәр гашыйк та итәрлек сценалар мине исә тәмам буйсындырдылар. Мин Рәшидә җыр-

[1] Антуан Мари Жан-Батист Роже де Сент-Экзюпери (1900–1944) – француз язучысы, профессиональ очучы.

[2] Эрих Мария Ремарк (1898–1970) – күренекле немец язучысы. 1950–1960 елларда СССРда киң танылу ала.

[3] А. Еникинең 1962 елда язылган повесте.

лаган авыл клубын, андагы фәкыйрь, ярлы авыл агайларын, апаларын, аларның тыйнак, ләкин чиксез бай күңелләрен күреп хәйран калдым. Татар авылында бара иде вакыйгалар, татар халкы арасында. Халыкның милли характеры, аның йөзе тик сезнең әсәрләрдә генә чын чагылыш таба дип уйладым мин шул чакта. Һәм үземдә гаҗәеп бер үзгәреш сиздем. Сезнең әсәрләрдән соң минем татарлыгым көчәя, мин үз милләтемне, үз халкымны, үз телемне, үз җиремне ныграк, ачыграк, яктырак, тулырак тоям икән...

Мин китаплардан алган тойгыларымны, тәэсирләремне язып та, сөйләп тә өйрәнмәгәнмен, тик ул өзекне укыган минутларда сез минем өчен бөек хаким, намуслы кеше идегез. Сез кайбер авторлар кебек назландырып, яулык астыннан гына карап торучы көяз түгел идегез.

«Менә кем ул Әмирхан Еники! Аның кемне сөюен, кемгә карап нәфрәтләнүен күрәсезме?» дип кычкырып тора иде ул өзек...

Быел, 11 майда, тагын шул ук өйгә кайтып төштем. Юл бик каты йончыткан иде, йөрәгем начарланып, төшкә кадәр интегеп яткан идем. Әни тагын бер көлтә журнал китереп бирде, һәм мин сезнең «Матурлык» хикәясен укып чыктым...

Әмирхан абый!

Аналар хакында күп язылган. Отышлы тема ул, тик сезнең хикәягез – шул күпсанлы әсәрләр арасында иң шәпләреннән берсе. Чын күңелдән әйтәм, укыдым да, мин шаккаттым. Үземдә ниндидер хисләр өермәсе күтәрелде, тыела алмыйм, нидер әйтәсем, нидер эшлисем килә, дуылдап уянган хисләргә исем дә таба алмыйм. Шундый сәер бер кичерешләр белән яшәдем мин бу көннәрдә. Хикәягез искиткеч. Сез үзегезнең ни язуыгызны аңладыгыз микән? Бу бит, бу бит – бик югары мастерлык! Кыска гына әсәр эчендә никадәрле минем җанга якын кешеләр. Ак сакаллы, актан киенгән сукыр татар карты... Бәдретдиннең әтисе... Үзе... Һәм, ниһаять, әнисе! Болар бит Микеланджело[1] кулы белән ясалганнар. Мин авыл читендәге шул фәкыйрь өйдә булдым. Шул өйдә булуым белән мин бәхетле идем. Бәдретдиннең скрипкәсе миңа

[1] Микеланджело Буонарроти (1475–1564) – Италия скульпторы, рәссамы, архитекторы.

иң матур музыка коралыдыр кебек тоелды... Аның әнисе миңа иң матур хатындыр кебек күренде. Йә, Ходай! Каян табып бетерәсез шулкадәр нечкә күңел кылларын! Шулар өстенә, болар бит барысы да тик татар авылында гына булырга мөмкин, безнең, минем халкым арасында гына... Хикәя турында язарга гына җыенам да тыелып калам. Аның хакында берничек тә аңлашып булмас кебек, андагы мәгънә матурлыгын, гүзәллекне берничек тә сөйләп биреп булмас кебек. Сез – зур язучы, Әмирхан абый, зур талант! Сезнең шундый булуыгыз миңа бик рәхәт бүген. Зур гына җаваплы иптәшләрдән[1] берәү минем «Өч аршын җир» кебек әйберләр язуымны «Әмирхан Еники тәэсирендә язмыймы ул малай?» дип, шундый ук җаваплы иптәшләрнең берсенә сорау биргән. Дөрес, минем кайдадыр сезнең белән килешмәгән чакларым да еш була, ләкин мин бүген сезнең алдыгызда башымны иям. Чын күңелдән олылыйм! Бәхетле кеше сез! Сез – герой, шуңа күрә фарисей Фасиевлар сездән куркалар да. Алар сизенәләр, тик телләре бәйләнгән, барын да әйтә генә алмыйлар. Алар да герой булырга бик теләрләр иде, ләкин язмыш аларны алай итмәгән, бәйдәге көчекләр ясаган. Бәйдәге эт усал булса да, бәйдә инде ул. Өрә, өрә, тик гомерендә берәүне дә тешли алмый. Бавы кыска. Озын итәр иде, хуҗа үзе дә шүрли. Азып китеп үзенең ботыннан каптырмасын!..

Ә Бәдретдин... Шундый кот очарлык ямьсезлекне матур итеп күрә белер өчен нинди бай кеше булырга кирәк... Тик без андыйлар түгел шул! Без үз ярлылыгыбыздан чирканабыз, якыннарыбызның ямьсезлеген тырышып яшерәбез. Безгә киң күңеллелек җитми... Ә Бәдретдин... Ошады ул егет миңа! Кызыктым мин аның кебек булырга...

Тик нигә хикәяне «карт әдип авызыннан» дип куйдыгыз. Кирәкми иде. Элегрәк мин Паустовскийның кечкенә әйберләрен шактый тәэсирләнеп укый идем. Яшь чагымда иң көчле тәэсир иткән әйберләрнең берсе К. Паустовскийның[2]

[1] Обком секретаре Фикрәт Табиевның Рәис Кыям улы Беляевка – комсомол обкомы секретарена әйткән сүзләре.

[2] Константин Георгиевич Паустовский (1892–1968) – рус совет язучысы, XX гасыр әдәбиятының классигы.

«Җитәкләүче» («Поводырь») хикәясе[1] булды. Мин аны русча белмәгән чакта ук, татарча «Совет әдәбияты» журналында укыган идем. Соңра аның «Корзина с еловыми шишками»[2] дигән хикәясен яраткан идем. «Матурлык» барын да узып китте. Мин аны повесть дип куяр идем. Нигә, бер дә гаҗәп түгел. «Карт әдип авызыннан» дип язу ничектер, кем алдындадыр акланып маташкан кебек килеп чыкмыймы?..

Инде ике-өч көн хат язарга җыенып, сүзләр, фикерләр өермәсенә уралып йөрдем. Язып бетергәч кенә сүзләремнең артык гади, хәтта таушалып төссезләнгән сыман булуларын да күрдем. Сез анысына игътибар итмәгез инде. Минем күңелем бу көннәрдә Сезгә рәхмәт хисләре белән тулы, мин Сезне яратып һәм сагынып, эшчән кулларыгызны кысып калам.

Сәлам белән АЯЗ.

И. ГЫЙЗӘТУЛЛИНГА
7 май, 1964 ел, Казан

Искәндәр!

17 апрельдә язган хатың кулыма килеп эләкте дә, мин аны тагын бер кат дулкынланып укып чыктым. Бүген комедияне[3] сиңа җибәрәм дип торам, озак тотты, дип ачуланма. Соңгы көннәр шуның сәхнә вариантына үзгәрешләр кертеп үтте. Шуңа күрәме, кәеф тә шәп үк булмады. Үзгәрешләрнең җан теләмәгәннәре дә бик күп булды! Мин аларын сиңа саласы вариантка кертеп тә тормадым. Комедия үземә дә ошамый хәзер. Төп фикер каядыр югалды, ниндидер ялган пафос алды кебек. Син укып, танышып чык, бары шуның өчен генә салам, ошар дип уйламыйм. Беренче кисәге ару гына булса да, икенче кисәге әллә ничек өтек булып китте...

Комедияне салырга уйладым да соңгы хатыңдагы аерата мәгънәле тоелган бер сүзеңә җавап та язарга булдым. Синең белән сөйләшмәгәч, кем белән ачыктан-ачык сөйләшим соң?..

---

[1] К. Паустовскийның 1937 елда язылган хикәясе.

[2] К. Паустовскийның 1954 елда язылган хикәясе.

[3] «Яланаяклы кыз» әсәре турында сүз бара.

Син Ф. Хөсни[1] «смотрел на народ сверху»... «сочувствует, но чувствует дистанцию» дип язасың...

Бу җөмләләр миңа да чыбыркы белән суккан кебек булдылар. Чыннан да шулай бит! Мин дә нәкъ Ф. Хөсни кебек, халыкка, өстән булмаса да, бер – читтәнрәк карамыйммени? Арадагы ераклыкны сизмиммени? Һәм иң кызыгы (бәлки, иң аянычлысы да шундадыр!) мин бит моны үзем дә сизәм, хәтта юри читкәрәк китәргә тырышам.

Мисал өчен ерак та барасы түгел. Сиңа җавап язарга утыргач та мин үземнең Зәй блокнотларымны карап утырдым. «Зәй энҗеләре»н язардан элек Зәй, ГРЭС, авыллар тирәсендә шактый йөрдем, шактый уйландым бит мин... Тик уйларымның иң тирәннәре повестька кердеме? Юк бит! Алар яшертен генә йә көндәлдә (кайберләрен блокнотка төшерергә дә шүрләдем!), йә блокнот битләрендә калдылар. Бәлки, мин аларны иң кирәге дип санамаганмындыр? Алай түгел шул: үземне иң борчыганнары, мине кеше иткән, йөрәгемне борчыган уйлар читтә калды. Мин «Өч аршын»да әле кайдадыр чын фикерләремне яза алсам да, «Зәй энҗеләре»ндә бу чынлык ясалмалык белән күмелеп калды. Менә блокнотка гына күз салыйк...

«Көнделемнең кәгъбәсе булган Зәй якларына кайтып иман яңартып йөрим. Карап та, күреп тә туймам мин бу якларны. Кайткан саен Югары авыл белән Түбән авыл арасындагы юллардан, елга буйларыннан, таулардан әйләнеп чыгам. Югары авыл зыяраты өстендә тирән бер коры елга бар. Үлән дә рәтләп үсми шул тауда, анда-монда сибелгән юка ак ташлар арасыннан үлән мыеклары гына тырпаеп тора. Нигәдер шушы ташлы тауда мин үземнең фәкыйрь халкым, мескен халкым, җәбер-җәфа күргән халкым, кыйналган халкым, моңлы халкым турында уйлыйм... Аның язмышы шушы ташлы тау кебек күренә миңа. Җилләр яргалаган аны, яңгырлар телгәләгән... Түбәндә генә – шыр ялангач зыярат»...

[1] Фатих Хөснетдин улы Хөснетдинев (1908–1996) – язучы, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1972), халык язучысы (1993).

Хәзер утырам да, нигә яздым икән бу юлларны? Бу кисәкнең асыл мәгънәсе, күңелемдәгесе нәрсәдә иде соң? Әһә! Менә болай иде бит...

Баграж авылы... Элек чын татарлар булган монда. Аннары аларны чукындырганнар. 1848 елны салынган агач чиркәү хәзер дә исән. Аларның борынгылыгы кайбер фамилияләрдә әле дә сакланган. Тугашовлар бар. Нинди матур борынгы татар фамилиясе! «Тугаш», «Тук-аш». Тугашлар тыкырыгы бар. Иң гаҗәбе: шушы бәләкәч кенә авылның ике нәни генә елгасына кемнәрдер «Чүке», «Чуал» исеме биргәннәр. Кара син аны, димәк, монда татарлар бик борынгыдан яшиләр булса кирәк. Чөнки төрки телләрдә «су-чү» формасы – бик борынгы мәгънә ич ул! Син географиядән Чу, Чулым елгаларын беләсең ич! Димәк, менә шушы Баграж авылы кешеләре дә шул төрки тамырларга барып тоташмыйлармыни? Нигә чукындырганнар әле аларны? Шушы бормалана-сырмалана агып яткан бәләкәй инешләргә Чуал, Чүке исеме бирә алырлык Тугашовлар нигә Иван да Чтапан булып киткәннәр? Чормаларында «Йосыф-Зөләйха»лар[1], «Нуры сыдур»[2]лар урынына «Матфей язган ару Евангелие»ләрне саклый башлаганнар? Повестьта Давыт образы бар. Ул бит керәшен. Син аның җырына гына игътибар ит:

Акырын кирәк, ипләп кирәк
Ишетергә сандугач сайрауларын...

Бу – чып-чын керәшен җыры. Нигә мин аны татарга әйләндердем? Ни өчен? Зәй буйлары өчен аерата характерлы булган чукындыру күренешеннән күз йомып кына үтәр өченме? Ни өчен мондагы татарлар чукынганнар соң?

Тагын блокнотка күз салыйк әле.

«Әле генә Ирнә елгасы буеннан йөреп кайттым. Минем эзгә үк басып, эңгер-меңгер төште. Күктә – өлгергән кавын телеме кебек ай. Көнбатышка сыек болытлар тартылган. Текә ярлар. Текә ярдан сикерә-сикерә төшәсең дә күз алдында – тал куаклары белән капланган бик матур тигез болын. Рәхәт! Көз булса да матур! Агач яфраклары тутланып җиргә коелганнар. Шулай да тал әрәмәсе матур. Таллы ярлар кысасында

[1] Кол Гали «Кыйссаи Йосыф» (1233), төрки-татар ядкяре.

[2] Мөхәммәдьярның поэмасы (1542).

юаш кына агып яткан елганы озак кына карап тордым. Текә ярдан, миннән куркып, бер кош очып китте. Сайрап куйган булды, мескен. Бу минутта мин үземне нигәдер шул кошка охшаттым...

Күңелемә төрле көйләрдән өзекләр килде. Туган җирләрем... Туган җирләрем... Әллә ничек күңел тулды... Җыр шыңшыдым... Күземнән яшьләр агып чыкты. Туган җирне сөеп, туган җиремә тамган яшьләрем. Минем бичара халкым! Ниләр генә күрмәдең син? Сине астылар, кистеләр, туган бишегең Казаннан утыз биш чакрымга куып җибәрделәр. Менә шушы Зәй, Ирнә буйларына, сине буйсындырыр өчен, крепость кебек нәрсәләр салдылар. Сине урмансыз кыр-яланнарга кудылар. Син җир өчен дип иманыңны саттың, чукындың. Син җир алу өчен дип күңелеңне каралттың, милләтеңнән ваз кичеп, «башкорт» булып йөрдең... Мескен халкым, бичара татарым минем! Гомерең буе кимсенеп яшәп, фәкыйрьлектә, нужада яшәп, син үзеңнең батырлыгыңны да, горурлыгыңны да күрсәтә алмый килдең. Синең моңың гына калды. Моңыңны сакладың син! Мич арасында, төтенле кара мунчаларда, төнге учак янында ат көткәннәрдә җырлап булса да, моңыңны сакладың. Шул моңлы җырларны шыңшып, бабайларның каны, тире түгелгән елга буенда йөргәндә ничек җыламыйсың? Үзеңнең бер сүз әйтә алмавыңны, көчсезлегеңне тоеп җылыйсың. Сиңа бәхет, рәхәтлек бирә алмый калу әрнүеннән җылыйсың. Туган җирне сөеп җылау оятмы әллә миңа?

Зәй өстендә аҗаган уйный. Әйе, безнең туган якларыбызның байлыгын ачтылар. Безнең халыкның байлыгын ачучылар гына юк. Тукайлар кирәк безгә, Тукайлар! Дөньякүләм яңгырарлык әсәрләр тудырырга кирәк! Кирәк!»

Күрәсеңме, Искәндәр, Зәй буйларында йөргәндә: 1960 елның сентябрендә ничек каты язганмын мин? Блокнотка шулай язылган. Ә күңел һәм куллар синең алдагы «Зәй энҗеләре»н иҗат иткәннәр...

Нигә алай? Нигә мин шушы тойгылар-хисләр белән янып йөргәнмен әле? Нигә мондый уйлар нәкъ әнә Зәйгә баргач туганнар?

Зәй... Тегенди-мондый гына урын түгел ул – тарихи урын! Мин аның ташландык борынгы зыяратын карап йөрдем. Кулымда сиңа төбәп кенә күрсәтерлек дәлилләр булмаса да, мин Зәйнең борынгы крепость икәнлеген беләм. Руслар татар ханлыгын яулап алгач, Зәй буйларына да үтеп кергәннәр, урманлы-сулы урыннарга урысларны урнаштырганнар. Татарларга урмансыз, сусыз кыр яклары гына калган. Шунда йөргәндә, минем хәтергә Норлат районында очраган бер татар искә төште. Шул кеше «авылда татарлар, йә булмаса руслар икәнлеген берәүдән дә сорамыйча белеп була: чокыр-чакыр, ташлы-тау тирәсендә татарлар утыра, ә елга буйларында, уйсу матур болыннарга рус авыллары урнашкан» дигән иде ул. Зәй буйларында әллә шул сүз хәтеремә төштеме икән? Чыннан да Зәй елгасы буенда башыннан ахырына кадәр диярлек татар авыллары юк икән бит!..

Рус туганнарыбыз килгәч, татарларга күченергә туры килгән. Син бу күченүләрнең ничек булганын беләсеңме? Урыслар Казанны алгач, татарларны куып җибәргәннәр һәм утыз биш чакрымнан да якында урнашмаска боерганнар. Казан тирәсендә утыз биш чакрым ераклыкта канлы межалар бар, дип сөйлиләр. Имеш, кайчандыр бу межалардан тулып кан аккан...

Үз җиреңдә каласың киләме? Рәхим ит! Тик иң элек чукын! Рус динен ал, фамилияңне үзгәрт! Һәм шуннан менә Иваннар, Чтапаннар килеп чыккан. Сарман ягы татарлары, җир алыр өчен, башкорт булып киткәннәр. Чөнки патша хәзрәтләре башкортларга җирне күп итеп бирә торган булган...

Шушы уйлар килгәндерме минем башка, икенчеләреме, әмма болар турында уйлавым шиксез...

Повестьта бер нәрсәгә игътибар иттеңме? Башта Гәрәй Шамин рус иде бит. Соңыннан мин аны татарга әйләндердем. Татарга әйләндергәч бер сорау туды: каян килгән ул, кайсы як татары? Мин моны белеп торып күрсәтмәдем. Чөнки татар халкының тарихы юк, мин ул тарихка борылып карарга куркам. Без тарихны Каюм Насыйридан[1], йә булма-

[1] Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров (1825–1902) – мәгърифәтче, тарихчы, этнограф, тел белгече, әдип.

са аннан элгәре яшәгән Утыз Имәнидән[1] башлыйбыз. Утыз Имәни «татар тормышында кырык фарыз булса, мин кырык беренчесен өстим, ул – рус телен белмәк» дигән. Каюм Насыйрины беләсең инде. Акыллы кешеләр булганнар! Шиксез! Тик тарихны нәкъ әнә шул фикерләрдән генә башлау – бүгенге көнгә кадәр үзенең телен, гореф-гадәтләрен саклаган биш миллионлы халыкны ярлыландыру түгелме соң ул?

Күрәсеңме, мин юри, аңлы рәвештә, Зәйнең тарихына, аның географиясенә күз сала алмадым. Мин белгәннәремне онытып торырга тырыштым, мин кушылганын гына күрергә, боерганын гына язарга мәҗбүр идем. Кайсыбер урыннарда бу мәсьәлә кискенлеге белән, үткенлеге белән көн тәртибендә тормаса да, борынгы Зәйдә, тарих юллары кисешкән, чәбәләнгән бер урында, халыклар тыгыз аралашкан төбәктә тарих, әлбәттә, кызык һәм гыйбрәтле иде. Син миннән чит уйлар эзләмә, мин әллә кайчангы ыгы-зыгыларны кузгатып, халыклар арасында дошманлык, яисә аңлашылмаулар тудырырга, чүплектә казынырга теләмим. Һич юк! Милләтемне сөйсәм дә, бу сөю миңа күкрәгемдә башкаларны сыендырырга да урын бирә! Тик тарихны бер яклы гына карау, бер максатны гына күздә тотып язу безне дөреслектән йөз чөерергә, ялганларга һәм өстән-өстән генә ермачларга өйрәтмәдемени?

Әле монысы бар. Бәлки, менә мин осталыгым, талантым җитмәгәнгә генә әнә шул четерекле, сизелеп торган тирәнлекләрдән читкә китәмдер? Талантым кечкенә булганга, ышандыру көчем аз булганга чирәм күтәрергә базмыйча, сөрелгән, тырмаланган җирне генә аннан-моннан эшкәртеп барамдыр? Бусы да ихтимал.

Тик мин бер нәрсәне ачык беләм: без барыбыз да өстен торырга өйрәнгәнбез. Яисә бер читтә торырга. Заман үзе шуны кушкан. Заман безнең кулга сукыр карталар тоттырган, менә сезгә карта, сызыклары сызылган, меридиан-паралельләре куелган, елга-күлләре бар, сезгә исемнәрен генә тутырырга калган. Безнең язучылар озак еллар сукыр карта

[1] Габдерәхим бине Госман бине Сәрмәки бине Кырым Утыз Имәни әл-Болгари (1754–1834) – шагыйрь, мәгърифәтче, галим һәм җәмәгать эшлеклесе.

тутырып утыручылар булмадымыни? Мин шулар эзеннән барам түгелме? Алар сызган ызан тирәсеннән атлыйм түгелме? Бер якка керә башласам, колак төбемдә «әй, ягалай!» дип кычкырмыйлармы?..

Фатих абый да – шундый ук заман корбаннарының берсе. Заманында үзенчәлекле, үзенчә яза башлаган кеше иде ул. Ә аның ул беренче адымнарын ничек каршы алдылар? «Кулак идеологиясе җырчысы, эстет, буржуаз-эстет, Көнбатышка баш июче» фәлән-төгән дип, азмы кычкырдылар?! Ныгып та бетмәгән Фатих Хөсни сыгылды, курыкты, башын иңбашларына яшерде... Син аның «Кырык хикәя» дигән җыентыгын[1] күрмәдеңме? Ул кырык хикәя тарау вакытта алай күзгә дә бәрелеп тормый иде, менә болай бергә туплагач, кызык кына бер нәрсә ачылды. Фатих абый хикәяләреннән чыгып, колхозлар турында нинди яңа законнар чыкканын күзәтергә була. Нинди яңа закон чыкса да, ул шуңа «отклик» яза барган. Югарыда төчкерсәләр, ул «исәнлеккә-саулыкка» дип кенә утырган икән. «Көнбатышка иярүдән өркеп», язучы кеше көндәлек хуҗалык законнарына гына ябышып барган түгелме?..

Дөрес, язучы үз намусы белән сәүдә итмәскә тиеш, әгәр чынлыкны әйтә алмыйсың икән инде; тын, эндәшмә! Тик без намус белән дә сәүдә итәргә өйрәнгәнбез инде. Безнең фаҗигабез шунда – без гражданнар түгел, революционерлар түгел. Менә хәзер культ заманында утырган кешеләрне, гаепсезгә утырганнар, фәлән-төгән, гаепсезгә атылганнар, дип сөйлиләр. Ә мин бу сүзләрдә коточкыч бер нәрсә ишетәм. Юк, алар ул заман өчен, Сталин каршысында гаепле иделәр, алар намуслы кешеләр иде, алар Сталин законнары белән килешеп торырга теләмәделәр, аларда революцион рух бар иде, дип кычкырасым килә. Әгәр алар да Сталин каршысында гаепле түгелләр икән, без ике йөз миллион халык шул кәрлә грузин алдында тавышсыз-өнсез басып тордыкмени?! Ичмасам, үлгәннәргә намуслылыкны бирик, алар – чын кешеләр иде, дип инаныйк, тереләрнең Сталинның күтен ялаулары

[1] Хөсни Ф. Кырык хикәя.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1960.– 256 б.

күз алдыбызда бит. Ичмасам, үлгәннәр кеше иде, дип юаныйк...

Мин Зәйгә баргач, блокнотымның бер почмагына «мин монда эшчеләр белән очрашудан гаҗиз, алар белән очрашасым килми, алар артык зарланалар» дип теркәп куйганмын...

Юккамы әллә бу? Мин әнә шул зарлану тәэсиреннән курыкканмын. Начальство белән сөйләшү кулайрак; ул дәрәҗәсен, урынын белеп кенә, артыгын чәпчемичә генә сөйләшә. Шома сөйләшә, артык-портык борылышлар да ясамый. Ә эшчегә аңа нәрсә? Ул тота да дөреслекне күзеңә бәрә, ә дөреслек кайвакытта ярап ук бетми шул.

Повестьны язганда бер шуларны гына күңел сандыгымда бикләп калдырдыммы мин? Юк, Искәндәр, башка бик күп мин «значительно» һәм «важно» дип санаган нәрсәләр дә әнә шулай ирексездән бикләнеп ятып калдылар. Куркаклыкмы бу, намуссызлыкмы – белмим. Тормышта күргәннәрнең уңай якларын гына язарга тырышмыйм мин, тормышның үзен – чынын бирергә тырышам. Тик язучы тормышта башка кешеләр күргәнне дә, алар тойганны да бирә алырга, халык белән аваздаш сөйләргә тиеш. Тик менә монысына, татар язучылары, өйрәнмәгәнбез...

Моңарчы шулай булды.

Хәзер инде заманалар үзгәрә төште. Еллар белән без дә үзгәрәбез. Менә шундый көннәрдә үз күңелеңне ачып сала торган әсәрләр урынына өстән-өстән генә ермачланган мемуарлар язу – бу җинаять. Бер мәртәбә булса да халык алдында, үз алдында чынлыкны ачып салырга йөрәксенергә, батыраерга кирәк иде...

Менә шул.

Бу хатны 7сендә яза башлаган идем, бүген иртән, 9 майда гына тәмам иттем. Иртәгә, Аллаһы боерса, мин гаиләмне алып, авылга кайтып китәм. Тик юлга илле-алтмыш сум акча табарга кирәк әле... Мин 23 июньнән Рижское взморьега, санаторийга путевка алдым. Июньнең 20ләренә кадәр минем адрес шулай булачак:

Тат. АССР, Заинского района, дер. Средне-Багряж

Гилязову А. М.

Өзек-өзек яздым, китү мәшәкате белән эшләрем дә күп булды, син минем фикерне аңларсыңмы икән инде. Ярар, хәерле булсын. Шушы җәһәттән авылга кайткач тагын язасы сүзләрем күп әле. Син мине кыздырдың.

Хуш булып тор. Авылда синнән хатлар көтәм.

Гаиләңә сәлам. Кулыңны кысып, АЯЗ.

Я. ЗӘНКИЕВКӘ[1]
22 декабрь, 1970 ел. Казан

Кадерле Якуб агай[2]!

Ниндидер сәбәпләр аркасында казага калган намазларын җыеп укучы диндар агай шикелле, мин дә, быелгы елның үтәлмәгән эшләрен тизрәк башкарып чыгасы иде дип чапаланам, шуларның берсе, менә бик күптәннән сезгә хат язарга җыенып йөрим.

Әйе, бик күптәннән. Сөйләшәсе килгән чаклар еш була, башны кая алып олагырга белмәгән көннәр күбәя баралар. Нинди планнар белән яши башлаган идек бит! Хәтерегездәме, сездә, Себердә чакта, мин: «Тарих белән кызыксынырга, ул турыда авыз тутырып язарга мөмкинлекләр туды», — дип сөйләнеп йөргән идем... 68 нче елның җәе бу планнарның буш, кирәксез һәм кирәксез икәнлеген кисәтте дә куйды...

Әйе, кызык хәлләр кичте баштан!.. Талантлар тантана итәргә тиешле мәйданнарга яңадан ялагайлар, төссезләр, хаиннар, ялганчылар, намуссызлар үрмәләп килеп чыктылар. Алар бит һәр минут әзер торалар иде, сагалыйлар, көтәләр генә иде. Сизәсездер, әдәбиятта чүп-чар бик күбәйде, «Казан утлары» журналының сыйфаты бик арзанланды. Гомумән, безнең язучылар арасында мөнәсәбәтләр бик нык үзгәрде. Кешеләр тынып, юашланып калдылар, ачыктан-ачык сөй-

---

[1] А. Гыйләҗевнең Я. Зәнкиевкә язган хаты язучының «Сайланма әсәрләр»енең 3 нче томына кертелгән (Казан: Татар. кит. нәшр, 2015, 560–562 б.).

[2] Якуб Камали улы Зәнкиев (1917–2003) – язучы, журналист, РСФСРның атказанган укытучысы (1957), Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2002).

ләшүләр тукталды диярлек, җыелабыз да йә бер-беребезне мактыйбыз, җыелабыз да бер-беребезне ялганлыйбыз.

Дөньяда иң куркыныч нәрсә – ялганларга өйрәнгән авыз. Ул тыела алмый, ак белән караны аерудан туктый, тыңлаучылар да аның ялганына, ниһаять, күнегәләр. Әле менә соңгы көннәрдә генә «Соц. Татарстан» газетасы Мөхәммәт Садри[1], Рамазан Байтимиров[2] кебек кешеләрнең шигырьләрен бастырып чыгарды. Бу кешеләр Ленин турында язарга батырчылык итәләр!.. Әгәр Сталин булса, алар шул ук тонда, шул ук сүзләр белән язарлар иде һәм яздылар да. Хрущевка багышлап та нәкъ шушындый ук нәрсәләрне әвәли алырлар иде. Яки Ивановка, Сидоровка!.. Буп-буш сүзләр белән күңел бушлыгын, күңелнең сатлык икәнен яшереп була бит, нишлисең. Кемнәрдер шул шигырьләрне басалар, чөнки моның бер куркынычы да юк. Фикер генә булмасын, укучылар әдәби әсәр укыгач уйланмасыннар, Ходай сакласын анысыннан! Менә сезгә арзанлы, ләкин уйсыз-фикерсез әдәбият, көн дә күшәгез шуны!

Язучы исеме шул кадәр ямьсезләнде, аның бернинди авторитеты, дәрәҗәсе юк. Чөнки халык каләм ияләренә ышанмый, аларга сагаеп, бер үк вакытта шикләнеп карый. Аннан республика оешмалары алдында татар язучысының дәрәҗәсе шулкадәрле бәләкәй, аларны беркем санга сукмый. Югары оешмаларда берничә талантсыз, ялагай кешене генә язучы итеп санап йөртәләр. Күпчелек исемсез, төссез массага әверелгән. Менә Хәсән Туфанның 70 еллыгын уздырдылар. Шушы юбилейга әзерлек көннәрендә Илдар Юзиев[3] «җитмешкә җитәргә язмасын икән» дип әйтеп ычкындырган.

---

[1] Мөхәммәт Хәбибулла улы Садретдинов (1913–1999) – татар шагыйре, җырлар авторы, очерклар һәм хикәяләр остасы, тәрҗемәче. Бөек Ватан сугышында катнашкан. РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре.

[2] Рамазан Муллагали улы Байтимиров (1923–1989) – татар шагыйре.

[3] Илдар Гафур улы Юзеев (1933–2004) – Татарстанның халык шагыйре (1993), ТАССРның (1979) һәм РСФСРның (1983) атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге (1968), ТАССРның Г. Тукай исемендәге (1980) Дәүләт премияләре лауреаты.

Миңа әйтмәде, башка берәүгә әйткән, әмма мин ул турыда сорагач «юк, юк, әйткәнем юк» дип, куркынып, үз сүзеннән баш тартты.

Ә бит Хәсән Туфан – безнең иң-иң атаклы шагыйребез дип йөртелә торган кеше, өлкә комитеты секретарьларының якын дусты, киңәшчесе. Шулай дип санап йөртәләр иде, ә ул бүгенге көннең мәзәкчесе, гап-гади шамакай гына икән. Дөрес, боларның бөтенесен дә каплау өчен аңа орден да бирерләр, әмма без белеп, без күреп торган хәлләрне ничек һәм кем каплый ала?!

Күңелләр төшенке, бик төшенке, Якуб агай. Кайсы буындадыр, нидер шартлап өзелде. Дус кына йөргән кешеләр белән аерылышып, таралышып беттек. Гел юк-барлар белән көн-сәгатьләрне генә түгел, елларны уздырабыз. Файдасызга үткән минутлар, кирәксез эшләргә багышланган гомерләр бик җәл, бик кызганыч...

Һаман эш тоткан булам тагын үзем...

Менә китапның[1] бер данәсен сезгә җибәрәм.

Русча тәрҗемәсе бетеп килә, шушы араларда тәмам була, дип хәбәр иттеләр. Димәк, киләсе елда ул русча да чыгачак. Тагын берничә әйбер яздым. «Урталыкта» исемле повестемны «Казан утлары» журналына[2] тапшырган идем, анда укыйлар, нәрсә диерләр. Аннары «Азат хатын»га[3] да нәни генә бер повесть бирдем[4]. Тулаем басмасалар да, берәр кисәге укучыга барып ирешер дип өметләнәм. Академия театрында яңа пьесама[5] репетицияләр башланды...

Кыймылдаган булам шунда, ә ажгырып, омтылып чабасы иде! Гомер бик тиз, бик кирәксезгә уза бит!..

Балалар иплә кенә укыйлар, өченче малай да үсеп, кеше булып килә. Без һаман алты җан утыз квадрат метрлы тар гына фатирда яшәп ятабыз. «Квартира бирәбез, зурай-

---

[1] «Урамнар артында яшел болын» китабы турында сүз бара (Казан: Татар. кит. нәшр., 1970.– 376 б.).

[2] Әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал.

[3] Иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис журнал.

[4] «Мөзәкир» турында сүз бара.

[5] «Эңгер-меңгер» турында сүз бара.

табыз»,– дип вәгъдә биргәннәр иде дә, булмас ахры... Ул турыда уйлаудан да ардым, туйдым.

Себер повестен[1] гел уйлап йөрим. Һичшиксез, сезгә барып кайтырга кирәк, язарга кирәк.

Менә ике ел инде нефтьчеләр янына барып йөрим. Шулар турында да әсәр язасым килә. Ничек барып чыгар. Быел кыш сәламәтлек тә әлләкем түгел, авырып, сыкрап йөрим. Күңел күтәренке булса авырмас та идек, күңелләр төшенке, бик төшенке...

Рәшидә ханымга[2], сезнең гаиләгә, мәктәптәге дусларга күп сәлам. Һәммәгезне дә яңа ел белән котлыйм, хат көтеп калам.

Сагынып, АЯЗ.

Я. ЗӘНКИЕВКӘ[3]
16 ноябрь, 1972 ел. Руза

Кадерле Якуб ага!

Бәйрәм котлавыгызны янә хатыгызны алып бик куансам да, Казанда чакта җитешеп хат яза алмадым. Аңа кадәр дә шактый мәшәкатьле чор кичереп, бәйрәм белән котларга да өлгереп булмады. Ике атналык командировкага Оренбургка барган идем, шуннан кайтканда, юлда, бераз салкын тидереп, бәйрәм алдыннан юеш борынны саклап, корык-корык ютәлли-ютәлли, өй ияләрен-бичураларны куркытып көнуздырдым.

Иң мөһиме болары түгел, чир килер дә китәр, иң яхшысы – сез сау-сәламәт эшләп ятасыз икән, күңелегездә һаман тынгысызлык уты дөрли, гомерегез озын булсын!

«Урталыкта» повестена карата әйткән фикерегез уйландырды. Дөрес, һәрбер әсәр күңелдә чакта, әле кәгазьгә төшеп өлгергәнче, алтын койрыклы, оҗмах кошы кебек мөкәммәл, шәп булып тоела. «Эх, дисең, менә бу юлы язам инде, кулга

[1] «Мең чакрым юл» турында сүз бара.

[2] Я. Зәнкиевнең тормыш иптәше.

[3] А. Гыйләҗевнең Я. Зәнкиевкә язган хаты язучының «Сайланма әсәрләр»енең 3 нче томына кертелгән (Казан: Татар. кит. нәшр, 2015, 598–602 б.)

шәп материал килеп төште!» Язып бетергәч, күңел аз-маз суына. Җитешсезлекләр дә, әйтеп бетерә алмаган нәрсәләр дә күзгә бәрелеп тора. «Урталыкта» повестеның җитешсезлекләре юк, дип расласам да, ул повесть, йөрәк каным белән сугарылган булганга, миңа бик якын, бик газиз. Бу повестьның кайбер мотивлары аңлатып бирүне, төшендерүне дә сорый торгандыр, әле исән-аман яшәсәк, бәлки, берәр тәнкыйтьче моны эшләп тә бирер. Әмма повестьны каралтып егарга чамалаучылар да юк түгел, хәтта Фәтих Хөсни агай да «Аяз кеше керендә казынырга ярата, иҗат юлы хәвефле булмагае» дип шөбһәләнеп, журналга мәкалә язып та китергән.

Кеше керендә түгел анысы, һич! Повестьта үзем, үз күңелем ачылып калды. Әгәр ул керле икән, анысы инде минем эш түгел. Анысын белмим. Повестьны якын кешемә багышладым, аңа карата күңелемдә инә очы хәтле дә кер юк – бусы да рас!

Быел минем «Кызлар хатлары» исемле китабым[1] басылып чыкты. Казанга кайткач та мин аны сезгә җибәрермен. Повестьның беркадәр тулырак варианты ул китапка да керде.

Менә һич көтмәгәндә, мин Мәскәүдән 100 чакрым ераклыктагы Иске Руза шәһәренә килеп чыктым. Монда драматургларның ике атналык семинары уза. Семинар өчен дип түгел, Мәскәүдә байтак йомышларым бар иде, шуларны башкарырга дип килдем. Аннары драматург агай-энене күреп, алар белән очрашып алу да чит нәрсә түгел. Кичә килеп төшеп урнаштык, бүген иртә таңнан торып сезгә хат язам.

Моның ике сәбәбе бар.

Беренчедән, сезне гаять дәрәҗәдә якын күрсәм, икенчедән, сезгә биргән вәгъдәм һаман үтәлми тора. Соңгы хатыгызда: «Кайчан була инде Себер повестьлары!» дип сорап та куйгансыз.

Әдәбият – бары тик күңел җимеше генә ул, монысын без икебез дә яхшы аңлыйбыз. Шушы кагыйдә бозылган тәкъдирдә бер генә язучының да уңышка ирешкәне юк әле. Мисалга ерак барып йөрисе дә түгел. Татарстанда нефть чыга башлагач та, без бик тырышып-тырышып, язучыларны шул

[1] А. Гыйләҗевнең 1972 елда басылган җыентыгы турында сүз бара.

төбәккә чакырдык. Дөрес, нефть темасы – зур тема, кирәкле тема, нефть чыгып, безнең халкыбызның тарихында, тормышында шактый гына үзгәрешләр тудырды. Әмма ләкин, күңеле тартмаган хәлдә дә, бары тик газеталарның баш мәкаләләре чакырганга гына ияреп, нефть турында язучылар азмы булды? Талантлы язучылар да күңелләрендә юкны бар ясарга тырышып, зур хаталар кылып ташлады. Рафаил Төхфәтуллин[1] исемле язучыны беләсез инде сез. Заманында чамадан тыш мактапып ташланды, үзәк матбугатта әсәрләре күренде. Мин, күңелемнең кайсы ягы беләндер, бер чакта да Төхфәтуллинга чын-чынлап ышанмадым. Очраклы кеше кебек тоелды ул миңа, аңа яну җитми иде, намуслылык җитми иде. Нәтиҗәдә, Р. Төхфәтуллин, зур язучы булмак теләге белән, Әлмәт шәһәренә күчеп килде һәм көзге юл янында караучысыз калган учак кебек бик тиз сүнде, сүрелде.

Сәбәп нидә иде? Нефть темасы Рафаилне кузгата алмады, дөресрәге, ул үзе бу теманы чишә алмады, кузгатмады. Коры теләк белән, бары тик кеше дәртләндереп торганга гына ышанып тотынган эш ясалмалыкка, ялганга, уенга илтә. Рафаил язучы буларак үзен-үзе нефтьтә үтерде. Беренчедән, аның әсәрләре күңел җимешләре булып туа алмадылар, икенчедән, Рафаил әдәбияттагы тагын бер мөһим канунны бозды, санга сукмады. Үз халкыннан, үз җирлегеннән аерылган авторларны әдәбият адым саен сагалап кына тора да түбәнә бәрә! Татар әдәбиятының хәзерге көндәге иң зур җитешсезлеге – безнең әсәрләрнең халкыбызның чын язмышыннан, чын тормышыннан, аның тарихыннан аерылган булуында. Шуны гына искәртеп китик: татарлар арасында нинди катлаулар, нинди кызыклы төркемнәр юк! Мишәрләр, Себер татарлары, типтәрләр, Касыйм татарлары, нократлылар һәм башкалар, һәм башкалар... Без тотабыз да Казан артының тасланган, юнылган, шоп-шома татары турында язарга тотынабыз! Менә мин керәшен авылында үстем, әмма, йөрәксенеп, шулар турында бер сүз яза алмыйм! Югыйсә, алар арасындагы кызыклы гореф-гадәтләр, уеннар, җырлар барыбыз өчен дә гаять кызык булыр иде. Гомәр ага Бәширов

[1] Рафаил Газиз улы Төхфәтуллин (1924–1994) – язучы, ТАССР-ның атказанган мәдәният хезмәткәре (1984).

«Туган ягым яшел бишек»тә керәшен темасын аз-маз тырмап уза, әгәр ул шул темага тирәнрәк, теләбрәк үтеп керсә икән, әсәр күп яктан баерак, тирәнрәк булыр иде.

Без, ирекләме-ирексезме, үзебезне үзебез ярлыландырабыз, үзебезнең тарихыбыздан чирканабыз, качабыз, аны язарга, ачыкларга куркабыз. Моның безнең ихтыярга буйсынмый торган сәбәпләре дә бар. Әйтик, керәшеннәр турында язарга алынасың икән инде, канлы патша Иван Грозныйларны, аларның буйсындыру, чукындыру сәясәтләрен азмы-күпме язмый үтеп тә булмас иде. Ә хәзер русларның бер иш катлауларында рус патшалары рәттән милли геройлар булып санала башлады. Шундый заманда патшаларга каршы чыгып та булмый торгандыр, бәлки. Әмма Гомәр Бәширов дигән исемең булганда, совет иленә шул тиклем хезмәт күрсәткән затка, курыкмыйча гына, аз-маз «тирәнрәк сөреп» карарга да яраган булыр иде.

Менә грузиннарны гына алыйк. Алар үзләренең этник төркемнәренә шул тиклем игътибар итәләр ки, шуның белән үзләрен гаҗәеп баеталар, башка халыкларны кызыктыралар. Хевсурлар, сваннар турында кем генә белми! Ә безнең мишәрләр турында чын итеп, кызыклы итеп, тарихка, этнографиягә, фольклорга таянып бер генә әсәр дә язганыбыз юк, дисәм дә хата булмас! Ә бүгенге көндә илгә-көнгә чыккан язучыларыбыз иҗатына игътибар итеп, Чыңгыз Айтматовны[1], Рәсүл Гамзатовларны[2] хәтергә төшерсәк, алар бары тик үз халыклары җирлегендә, үз халыклары матурлыгы югарылыгында гына дан казандылар. Чыңгызлар, Рәсүлләр бары тик үз халыкларын тирәнтен аңлап кына, аларның күңел

[1] Чыңгыз Торекулович Айтматов (1928–2008) – күренекле рус һәм кыргыз язучысы, дипломат. Кыргызстанның халык язучысы (1974), Социалистик Хезмәт Герое (1978), Ленин (1963) һәм СССР-ның Дәүләт премияләре (1968, 1977, 1983) лауреаты, Кыргыз республикасы Герое (1997).

[2] Рәсүл Гамзатович Гамзатов (1923–2003) – күренекле авар шагыйре, публицист. Дагыстан Республикасының халык шагыйре (1959), Социалистик Хезмәт Герое (1974), Сталин (1952) һәм Ленин (1963) премияләре лауреаты.

байлыкларына хуҗа булып, үз халыкларының тулы хокуклы вәкилләре рәвешендә дөньяга чыга алдылар.

Безнең дә талантлы язучыларыбыз бар, намуслы язучыларыбыз байтак... Беләм, татар халкының тарихы чуар, катлаулы, аның ачылмаган битләре, ачыкланмаган нәрсәләре бик күп. Безнең милли дастаныбыз «Идегәй»[1] эпосының да халык арасына чыга алганы юк. Мәскәүдән галимнәр «инде чыгарыр чак җитте, шул эшкә керешик» дигәч тә, безнең урындагы кайбер җитәкчеләр куркып калган икән, дигән хәбәрләр йөри.

Хас халыкныкы гына булган «Идегәй»нең дә дөнья күрми ятуын белгән язучыларның кайбер чакта шикләнеп калулары да ихтимал... Барысы да дөрес, әмма татар язучысының Чыңгызлар, Рәсүлләр кебек ялтырап килеп чыга алмавы да дөрес. Безне, язучыларны, хәзер укучылар нык кына кысалар. «Ничек алай, нигә берәү дә чыга алмый?» – дип, турыдан-туры сорыйлар. Оренбургта Хөсәен Ямашев исемендәге китапханәдә очрашкан чакта, миңа нык кына кызарырга туры килде. Чөнки әдәбиятта үлчәп карарлык зур фигуралар бар. Әдәбиятта намуслылык, чынлык үрнәкләре булырлык асыл затлар бар. Ә без һаман үз казаныбызда кайныйбыз, үз кабыгыбызның шакшы суында быкырдыйбыз...

Сизәсездер, кадерле Якуб ага, мин ничек як-якка ташланам! Бердән, шулай язмыйлар, болай эшләмиләр дип, каләмдәшләремә үпкәләсәм, икенчедән, аларның шулай яза алмауларына акларлык сәбәп тә эзләгән кебек булам. Нигә үзем яза алмыйм? Нигә үзем күтәреп, күтәрелеп чыкмыйм? Моның сәбәпләрен азмы-күпме әнә шул «Урталыкта» повестенда бирергә тырышкан идем дә инде. Әлбәттә, мин повестьны язучылар, артистлар тормышына багышлый алмадым, шуның өчен анда берникадәр ясалмалык, схематизм да бардыр. Әмма геройның – Сәгыйтьнең кичерешләре – алар үземнеке... Үз башымнан узганнар, үз күңелемне тетрәткәннәр. Мин үземнең уртача гына талант икәнлегемне, уртача гына кеше икәнлегемне ап-ачык белә торган кеше хәзер. Шуның өчен әллә кая очып та китә алмыйм, очмый торып та булмый, талпынган буласың шунда.

[1] Татар халык дастаны.

Сезгә барып, Себер повестьлары язып, шул чирәмнәрне кузгатырга ниятләп йөргәндә, әле мин яшьрәк идем, дәртлерәк идем, үземне пәйгамбәр итеп санамасам да, Себер чирәмнәрен генә кузгатырлык көчле итеп саный идем... «Бетте көч, сынды кылыч» димим, шулай да кылычны тартып алдылар. Бусы хак!

Себер повестьларын[1] хәлемнән килгәнчә, көчем җиткәнчә язачакмын, моңарчы ныклап эшкә тотынмый торуымның сәбәбе бер генә – материал җитми. Ясалмалыктан, уйдырмалардан котыласы иде. Чын итеп, халыкларны кузгатырлык итеп язасы иде аларны! Тагын бер кат Себергә барырга кирәк... Тагын бер кат Иртеш буйларында йөрергә кирәк, шунсыз ярамый, шунсыз барып чыкмый. Хәтерегездәме, мин сездән туй турында сораган идем. Сез «хәзер алар аракы белән күмелеп калдылар» дибрәк җавап яздыгыз. Кайчандыр алай булмагандыр ич! Миңа Себер татарларының милли төсмерләре кирәк. Башка халыклар өчен дә гыйбрәтле, кызыклы булырлык этнографик материаллар кирәк. Бәлки, бу алдагы җәйдә мин Себер сәфәрен тагын бер ясармын. Теге вакытта мин хисләргә ирекне күбрәк биргәнмен, хәзер акыл белән барыр идем. Ул чагында ни кирәген белеп тә бетермәгәнмен, хәзер аңлыйм, беләм...

Ни кирәген белү, үз-үзеңне белү – күңелле дә, күңелсез дә, Якуб ага.

Мин монда ноябрь ахырына тиклем булам, хатны Казанга гына язарсыз инде.

Себер повестьларын язарга кирәк.

Аны язуымны кичектерергә ярамый, җитәр. Мин сезнең алда бик бурычлымын. Бергәләп тотынганда без байтак нәрсәләрне ачыклый алырбыз дип уйлыйм. Һаман-һаман сезнең ярдәмгә өметләнергә туры килә, нишлисең, без кешеләрнең ярдәменә бик мохтаҗ. Иптәшлеккә мохтаҗ. Яхшы сүзгә, яхшы күңелләргә мохтаҗ.

Рәшидә ханымга, балаларга, дусларга күп сәлам!

Чирләмәгез, чиргә баш бирмәгез, яшәсен сәламәтлек!

Кулыгызны нык кысып, сагынып, АЯЗ.

---

[1] «Мең чакрым юл» һәм «Әтәч менгән читәнгә» турында сүз бара.

Н. ӘСӘНБАЕВКА[1]
31 март, 1975 ел. Казан

Нәҗип![2]

Хәлең белән таныштым. Саулыгың турында гына берни язмагансың. Язмагансың икән, шәп дип уйладым. Шулай булсын кана!

Килергә уйлаган вакытың безнең өчен дә кулай булыр. Димәк, апрельнең икенче яртысында?! Тынычлап кына хәләл җефетеңнең татлы юбилеен уздыр, көч җый һәм әйдә сәфәр! Мин үзем дә апрельнең беренче декадасында Әлмәткә барырга тиешмен, көне тәгаенләнмәгән. Анда дүрт-биш көн узар әле. Минем Казанда Академиядә[3] премьерам[4] 3 майда, менә шул.

Пьесамны[5] укыгансың, тыйнак кына мактагансың. Кирәкми иде. Мин үз язган әсәрләремнең урынын шулхәтле сиземлим, монысын мактарга кирәкмәс иде! Дөрес, кулымнан килгәнчә, мин ул әсәремдә дә туры, гадел һәм тугры булырга тырыштым. Әмма минем көчсезлегем – мин Ватан сугышын күрмәдем. Һәр язучының үзенә якын, үзе сайлаган һәм гомерлек юлдашы иткән темасы була. Язучы үз чордашлары алдында да, киләчәк буын алдында да мәгълүм бер чор өчен, билгеле бер тема өчен җаваплы. Бер язучы да бөтен дөньяны колачлый алмый ич. Толстой йөз томнар әсәр язган икән, бу әле йөз тема күтәрдең дигән сүз түгел! Толстой ике-өч теманы ала да, шулар тирәсендә, төрле яктан килә-килә, тирәнәйтеп, киңәйтеп, һаман үз сүзен үткәрә бара. Мин Толстой[6] белән үземне чагыштырырга һич тә җыенмыйм,

---

[1] А. Гыйләҗевнең Н. Әсәнбаевка язган хаты язучының «Сайланма әсәрләр»енең 4 нче томына кертелгән (Казан: Татар. кит. нәшр, 2015, 234–235 б.)

[2] Нәҗип Васил улы Әсәнбаев (Николай Васильевич Асанбаев, 1921–2013) – башкорт язучысы, шагыйрь, драматург. С. Юлаев исемендәге Республика премиясе лауреаты (1983).

[3] Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры.

[4] «Җиргә тапшырылган серләр» спектакле турында сүз бара.

[5] А. Гыйләҗевнең 1974–1975 елларда язылган «Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз» әсәре турында сүз бара.

[6] Лев Николаевич Толстой (1828–1910) – күренекле рус язучысы.

әмма мин үземнең темамны, үз урынымны тапкан кеше дип йөрим. Минем төп әсәрләрем сугыштан соңгы чорга багышланганнар. Сугыш чорындагы авыл һәм аның аннан соңгы еллары өчен татар әдәбиятында мин җавап бирәм. Әгәр мин бу чорны алдагы буыннар аңларлык, бәһаләрлек һәм тетерәнерлек итеп язалмаганмын икән, монда заманның күп төрле киртәләреннән тыш, мин дә гаепле.

Үзең кичермәгәнне язу, үзең белмәгәнгә тотыну – язучы өчен куркыныч. Мин сугыш темасында үземне егет итеп, ир итеп тоя алмадым. Һәр әсәргә керешер алдыннан, язучы кәләш куенына керергә җыенган егет хәлендә булырга тиеш. Таза, саф, чиста, егәрле һәм үз-үзенә бик нык ышанган хәлдә... Югыйсә... Менә мин бу пьесаны язганда үз көчсезлегемне тойдым. Моны артистлар да сизенде. Нәҗибә Ихсанова[1] Туфан[2] янына читкадан кайткач: «Аяз абыйның куян хәлен күргән юк иде, куян булып кына утырды»,– дип сөйләгән. Дөрес сизенгән, каһәр! Юк, Нәҗип, мактама минем бу пьесаны... Лек[3] та аны куям дип йөрмәсен, кирәкми. Булыр, табылыр...

Менә мин – 17 пьесаның авторы. Мин аларны бик яхшы беләм. Арада чын әсәрләрем бар, онытылмас әсәрләр. «Киек Каз Юлы»[4], «Җиргә тапшырылган серләр»[5], «Әңгер-

[1] Нәҗибә Гыймай кызы Ихсанова (1938–2021) – Татарстанның (1982) һәм Россиянең (2000) халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1998).

[2] Туфан Габдулла улы Миңнуллин (1935–2012) – күренекле драматург, язучы, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе. РСФСРның К. Станиславский исемендәге Дәүләт премиясе (1979), ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе (1979) лауреаты, ТАССРның (1978) һәм РСФСРның (1984) атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык язучысы (2005).

[3] Лек Вәли улы Вәлиев (1935–1992) – башкорт режиссёры, 1971–1981 елларда М. Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия драма театрының баш режиссёры. БАССРның (1972) һәм РСФСРның (1978) атказанган сәнгать эшлеклесе.

[4] А. Гыйләҗевнең 1960–1961 елларда язылган пьесасы.

[5] А. Гыйләҗевнең 1966–1967 елларда язылган пьесасы.

меңгер»[1], «Өч аршын җир»[2]... «Кара күзле кызлар»ны[3] да курка-куркарак шулар рәтенә кертәм. Ә калганнарына минем мөнәсәбәтем төрлечә...

Хәлең юк икәнне белә торып нигә язарга тотындың, диceңме? Мин язмасам, бу газиз темага халтурачылар тотынып, аны изеп, тагы да начар әсәр куячаклар иде. Менә шуңа тотындым. Мин сугышның үзен күрмәсәм дә, сугышка китеп башларын салган йөзләрчә кешеләрне күргән. Мин озатып калган иптәшләрем, классташларым: Җәкәү, Үткен Ибаны, Җәпүш, Җаграп дәдәйләр, мин сокланып йөргән егетләр – Кунун Бәчелие, Кайнарларның биш улы, башкалар... Мин соңгы сулышымда да ул кешеләрне оныта алмам. Гүзәл, акыллы кешеләр булганнар – Баграж керәшеннәре! Матур кешеләр... Менә шул кешеләр турында җылы бер сүз әйтер өчен генә алынган идем...

Сез укыган вариант нык үзгәрде, кыскарды, баеды, әмма барыбер мин ул пьесамнан куркам. Ялган бар төсле анда, фальшь... Үзең гомерең буе ялган һәм фальшь белән көрәш тә, мә сиңа, сугыш темасына язганда... бераз кыек кит!..

Нәҗип, болай итик без. Әгәр мөмкин булса, син пьесаңны шыпырт кына миңа җибәреп куй. Мин укып, беркемгә дә әйтмичә генә фикер җыя торырмын. Ярыймы?

Ярый, Наилә ханымга, балаларга бездин күп сәлам!

Дусларга сәлам әйтергә дә онытма!

Кулыңны кысып, сагынып, АЯЗ.

«КАЗАН УТЛАРЫ» РЕДАКЦИЯСЕНӘ

31 март, 1975 ел

Әйе, Салих Сәйдәшев яшәгән чор әле тарихка чорналып бетмәгән. Салих Сәйдәшевнең яхшы һәм яман чордашлары әле исән, алар кылган яхшылыклар да, яманлыклар да халык телендә. Чынлык белән бергә ялган да иркенләп, ирәеп йөри. Нишлисең. Зур агачка җил каты бәрелә!..

---

[1] А. Гыйләҗевнең 1968 елда язылган пьесасы.

[2] А. Гыйләҗевнең 1972 елда шул исемдәге повесте нигезендә язылган пьесасы.

[3] А. Гыйләҗевнең 1962–1963 елларда язылган пьесасы.

«Әмирхан Еники Сәйдәш турында әсәр яза икән» дигәч, кайбер кешеләрнең йокылары качкандыр. Без дә дикъкатебезне арттырмадыкмыни? Көтмәдекмени? Менә «Гөлəндәм туташ хатирәсе»[1] исемле кечкенә роман безнең кулда.

Сәйдәш турында язу авыр, дидек, һәм менә Әмирхан абый ул турыда язарга да мөмкинлек тапкан. Ул чишмәнең ургылып акккан чагына түгел, чишмәнең башына мөрәҗәгать иткән. Сәйдәшне Сәйдәш иткән елларга, композиторның гомер юлына җылы, шифалы җил булган яшьлек мәхәббәтенә... Шәп! Бик шәп! Оста язылган, Еникичә генә язылган роман (хәтта аның роман булуы да урынлы!) җырлап тора. Ул күңелгә үтеп керерлек кичерешләр, ул гомергә онытылмаслык табигать тасвирлары, ул татар халкы өчен гали зат булган шәхесләрнең кыска-кыска гына, әмма бик кирәкле урыннарда күренеп китүләре! Һәммәсе үз урынында, һәммәсе эчке мәгънәгә ия...

Күңелдә чак кына канәгатьсезлек уяткан ике урын булды: беренчесе, Гөләндәм туташның артык ялгызлыгы. Дөрес, әсәрнең башында ул кемнәндер китап алып кайткан икән... Шәһәрдәге кичәгә барганда да аның янына ике туташ керөп чыга... Ләкин болар гына бик аз. Чөнки Гөләндәм туташ бикләнеп кенә ята торган кеше түгел, чоры да башка. Кайсыдыр урында, берничә сызык белән, аның ялгыз түгеллеген искәртеп киткәндә дә ярар иде. Икенче искәрмәм шул: берара Салих романнан бөтенләй югалып тора. Эч поша башлый, сюжет киеренкелеге йомшара. Монда нидер эшләргә кирәк. Әсәрнең төп герое тукымадан читкә чыгып китә икән, монда героебыз герой булудан туктый түгелме? Димәк, моны да карарга кирәк.

Әсәрнең тел чатаклыкларын билгеләргә дип кулыма каләм алып утырган идем, булмады. Еникинең сихри теле бер биләп алды да, барысы онытылды...

Минемчә, роман журнал битләрендә лаеклы урынын алыр һәм укучы аны яратып кабул итәр. Озакка сузмыйча ук бастырып чыгарырга кирәк!

Аяз Гыйләҗев, 31 март, 1975 ел

---

[1] Ә. Еникинең 1975 елда язылган повесте.

Н. ӘСӘНБАЕВКА[1]
1 сентябрь, 1975 ел. Казан

Нәҗип!

Күңелләр бер шул безнең! Менә минем дә җәйге яллар, мәшәкатьләр узды, бүген-иртәгә хат язарга дип йөргәндә, үзеңнән хат! Әле журналны ала алган юк, сезгә барып та җиткән икән! Рәхмәт яхшы сүзләреңә! Син, мине яратканга, мактауны мулрак та җибәргәнсең, ләкин нишлисең... рәхәт шул, мактауны ишетү дә рәхәт! Ничек булыр, укучы ничек кабул итәр, дип борчылып йөргәндә, синнән, акыллы укучыдан (язучы да укучы була белә бит!) шундый хат алу күңелне нечкәртте...

Быел җәй эш белән узды. Берара авылга кайтырга дип планлаштырып йөргән идем, кайтмадым, башта чамасыз әшәке корылык булды, крестьянның авызы-борыны канлы чакларны күп күргән, ул чагында аның күзенә пәри булып йөрисем килмәде. Казаннан беркая чыкмадым, дисәң дә ярар, дачага да сирәк бардым, өйнең зурлыгына куана-куана, рәхәтләнеп бер эшләдем, малай. Әлмәт театрына[2] атап, «Кар астында кайнар чишмә»[3] исемле дүрт кешелек кенә җитди комедия яздым. Бусы булды июньдә. Июльдә Күчмә театрга[4] «Мәңгегә калам»[5] дигән өч пәрдәлек пьеса язып, аны Равилгә[6] укыдым. Яратты. Эшлисе бар, эшлисе күп, ләкин режиссер белән кул бирешкәч, эшләве дә күңелле бит, иеме?! Аннан августта «Күзгә-күз»[7] исемле дүрт табаклык повесть язып бетереп, менә узган җомгада нәшриятка илттем. Ул повесть, әнә син укыган ике повесть белән янәшә, китап

---

[1] А. Гыйләҗевнең Н. Әсәнбаевка язган хаты язучының «Сайланма әсәрләр»енең 4 нче томына кертелгән (Казан: Татар. кит. нәшр, 2015, 240–242 б.)

[2] 1944 елда колхоз-совхоз театры буларак ачыла, 1951 елдан – драма театры, 1985 елга кадәр – күчмә театр.

[3] А. Гыйләҗевнең 1975–1976 елларда язылган комедиясе.

[4] К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры.

[5] А. Гыйләҗевнең 1975 елда язылган пьесасы.

[6] Равил Рәхим улы Тумашев (1923–2016) – татар театр режиссеры, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

[7] А. Гыйләҗевнең 1976 елда язылган повесте.

булып 76 елда чыгарга тиеш. Бик ашыгыч, кылбырдак булды. Арган идем, шулай да кызык кына нәрсә килеп чыкты кебек. Менә редактор укый, рецензент алып китте... Бер җәйгә ике пьеса, бер повесть. Ярый бит, әй! Әлбәттә, пьесалар әле нык эшләнер, нык үзгәрер, әмма бер шәкеле булгач, үземне иркенрәк сизәм. Шулай да бик ардым, әмма күңелдә канәгатьләнү хисе дә бар. Эшләми узган гомер бик кызганыч шул хәзер! Гомернең яртысыннан бик күп артыгы узып киткәнне бөтен күзәнәкләр белән сизәсең икән аны!..

Хәзер алда – Гарифның юбилее. Мин докладчы. 26 сентябрьдә Төзүчеләр сараенда юбилей кичәсе. Шунда бер егерме минут речь тотарга кирәк. Шуның белән утырам...

Марсель[1] белән бүген шалтыратышып сөйләштек. Син, егет, давай, конкурс-конкурс дип торма, бездә серең ачылганчы әллә никадәр вакыт узар, Марсель аптырап тора. «Җибәрмәде», – ди. Иртәгә – Рәшидә Җиһаншинаны[2] директорлыктан тантаналы озату. Аның урынына курчак театры[3] директоры Әзһәр Миншәехович Хөсәенов[4] дигән сәер генә бер кеше килде. (Беләсеңдер син аны, элегрәк Минзәлә театрында[5] да директор булып эшләде.) Сәерлеге шунда: бик шикле кешеләр белән аралаша ул, җыен педераст белән бутала, юк кешеләргә таянып театрны харап итмәсә ярар иде,

---

[1] Марсель Хәким улы Сәлимҗанов (1934–2002) – мәшһүр татар режиссёры, педагог. ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1970), СССРның халык артисты (1984), Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1971), РСФСРның К. Станиславский исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1979), Россия Федерациясенең Театр эшлеклеләре берлегенең «Алтын битлек» бүләге иясе (2000).

[2] Рәшидә Габдуллаҗан кызы Җиһаншина (1917–2003) – Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының танылган сәхнә остасы, җәмәгать эшлеклесе, 1964–1975 елларда театрның директоры. ТАССРның (1966) һәм РСФСРның (1981) халык артисты.

[3] 1934 елда нигез салынган Татар дәүләт «Әкият» курчак театры.

[4] Әзһәр Миншәех улы Хөсәенов – 1975–1981 елларда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры.

[5] Ә. М. Хөсәенов турында сүз бара. 1967–1971 елларда ул Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә Татар дәүләт драма театрында директор вазифасын башкара.

дим! Марсель әйтә: «Миңа тәкъдим ителгән бөтен чудаклардан арурак инде»,– ди.

Театр болай Мәскәүдән ару гына кайтты. Газеталарда төрле бәяләр күренде. Килешердәе бар, килешмәстәе, Марсель ул барысын да үзенчә уйлый, үзенчә хәл итә. Аклана да белә, әмма киткән чакта ук: «Безне бүгенге көн репертуары белән нык кына ярачаклар, әгәр мин «Өч аршын җир»[1], «Ат караклары»н[2] һәм башка Диасның яңа пьесасын[3] алып барып күрсәтсәм, аларның авызы томаланыр иде, әмма болай нишләмәк кирәк!» – дип әрнеп киткән иде. Бүгенге көн репертуары юк, дип театрларны сүгәр өчен әллә ни кирәкми, әгәр инде син кыюлыгың җитеп, пәйгамбәрлегең көче белән, «бүгенге көн репертуарының ни өчен юклыгын» исбатлый алсаң икән?! Югыйсә, руста да әлләни баш китәрлек нәрсәләр юк ич.

Туфан Мәскәүгә ВЛКга[4] барам дип йөри иде, аның хәлләре дә нык үзгәреп китте. Инде үлә алмыйча, рак белән көрәшеп, әнисе ята... Әнисе менә үлә-менә үлә дип торганда гына әтисен машина таптап үтерде дә, әнисе караучысыз калды. Туфан Мәскәүгә китте, анда шул берәр атна була да, ике айга ял алып кайта. Әнисе янында кеше юк. Әле шул, китәр алдыннан гына, аның 40 еллыгын уздырдык, кунаклар шәп иде, күп иде, күңеле нечкәреп күзләреннән яшь тә түгелде малайның...

Менә уку елын башлап җибәрдек. Бүген мин бәләкәй улымны, төпчегемне беренче класска илттем! (Менә нинди хәлләр дә бар әле бездә, Нәҗип!) Минем дә күңелләр тулып, әллә нинди уйлар уйланылды, моңаелды...

Быел «Хаҗ сәфәреннән»[5] кайтканга да 20 ел. Үзенә күрә түгәрәк дата. Егерме елда байтак эшләнде. 19 пьеса язылды, роман, повестьлар... Күңел канәгать булмаса да, аз-маз тырмаштык... Тик заман, заман! Бик күп шул әле аңгыралар!

---

[1] «Өч аршын җир» повесте нигезендә язылган пьеса турында сүз бара.

[2] «Ат карагы» – Т. Миңнуллинның 1972 елда язылган пьесасы.

[3] Д. Вәлиевнең «Диалоги» (1976) дигән әсәре турында сүз бара.

[4] ВЛК – очучыларны тикшерә торган врачлар комиссиясе.

[5] Тоткынлыктан (1956) кайтуы турында сүз бара.

Хәзерге заманның иң ошамаган ягы шунда – талантсыз кешеләр, әрсезләр, комагайлар, аңгыралар, карьеристлар бик тиз югары урыннарга үрли алалар! Их, шул әшәке якны да җиңеп булса икән?! Партиясенә дә кереп куя ул шамакайлар, тормышта мөнәсәбәтләр дә көйләргә остара, нәтиҗәдә, талантлы кешеләр интегә! Шул җанны кыйный, шул рәнҗетә... Наданнарга исә бозау муенчагы, кыңгырау гына кирәк, әйдә шалтырасын аларга!..

Әлбәттә, тормышта яхшы кешеләр күбрәк. Әгәр ул шулай булмаса, талантлар, гомумән, яши алмас иде. Талант бары тик яхшы кешеләр арасында гына, яхшы кешеләргә генә аркаланып чәчәк ата, тормышның әйбәт кешеләре талантны алга әйдиләр. Яхшы иптәшләрем булды, хәзер дә бар алар, шуларның берсе – иң кече күңеллесе, иң гадие, иң гаделе – синдер, мөгаен, Нәҗип, мин шулай уйлыйм, миңа шулай уйлау рәхәт...

4 сентябрьдә гомуми җыелыш, РСФСР язучылары съездына делегатлар сайлыйбыз. Эшләгәндә кеше юк, кунак өстәле тирәсенә җыйналганда кашык җитми! Әрсезләр, талантсызлар союзга да үрләгән бит! Үрләгәннәр, үзебез дә үрләттек. Ныклык җитеп бетмәгән... тәҗрибә... акыл!

Кайара миңа иптәшләр үпкәлиләр... «Каты телле» син, диләр. Менә әлерәк кенә, редколлегия әгъзасы буларак, Барлас Камалның[1] «Йөрәкнең янулары»[2] исемле кульязмасын укып чыктым. Повестьнең минем кулга эләгүен ишетүгә, кара коелып: «Нәшриятта китапны егарга кирәк булса, Аязга бирәләр иде, хәзер журналда да шул хәл башланган икән»,– ди икән ул... Нәҗип! Бәлки, мин ялгышамдыр... Бәлки, минем алай нык булырга, таләп итәргә хакым да юктыр? Үземнең иҗатым да йомшактыр?! Әдәбиятта миннән алда башлаган, заманында бик мактаулы Барласлар шулай сөйләгәч, күңел борлыгып та ала... Аннан тукталам да уйлыйм... Юк, димен, «Өч аршын җир», «Берәү», «Урталыкта»,

[1] Барлас Хәмит улы Камалов (1930–2004) – язучы, ТАССРның (1980) һәм РСФСРның (1992) атказанган мәдәният хезмәткәре.

[2] Барлас Камал әсәре.

«Язгы кәрваннар»[1] повестьларын язган кеше таләп итә ала, урынлы, аның хакы бар, дип юанам.

Менә шуңа күрә синең хатың күңелдә әйбәт тойгылар уятты, мин сиңа озын гына итеп язып ташладым!

Дусларга: Рафаилга, Әсгатькә, Фәрит Исәнголга, Лек Вәлиевкә – һәрбарчасына сәлам тапшыр. Синең сәламеңне рәхәтләнеп ирештерермен...

Гаиләңә сәлам!

Уңыш теләп, АЯЗ. Авырма!!!!

М. МӘҺДИЕВКӘ[2]

14 март, 1976 ел, Руза

Мөхәммәт!

Драматург булуның шул рәхәте бар – һич көтмәгәндә, Мәскәүдә утыручы министрлык кешеләре «семинарга» дип чакырып алалар да, бер айлык ялга чакыралар! Илнең бөтен читеннән җыйналган адәмнәр белән очрашасың. Ачылып китәсең, корымланган күңелләр сафланып кала... Бу юлы да шулай булды. Әле съезд алдыннан гына таралышкан Рузага тагын җыелдык. Илдар[3] монда, Нәҗип Әсәнбай, кичә яшь Юныс Сафиуллин[4] да монда килеп төште. Бүген-иртәгә «Россия Федерациясе»нең атаклы делегациясенә Туфан да катнашып китәчәк. «Татарское нашествие» дип көлеп тә куялар...

Казаннан ычкынганнан бирле күңел көр генә, акырын гына җиңеләя бара... «Җиңеләю» сүзенең «җиңү» белән бер тамырдан икәненә соңгы вакытларда гына игътибар итә башладым...

Син ни хәлләрдә?

---

[1] А. Гыйләҗевнең 1972 елда язылган повесте.

[2] А. Гыйләҗевнең М. Мәһдиевкә язган хаты язучының «Сайланма әсәрләр»енең 4 нче томына кертелгән (Казан: Татар. кит. нәшр, 2015, 253–255 б.)

[3] Илдар Гафур улы Юзеев (1933–2004).

[4] Юныс Габдулла улы Сафиуллин (1947) – татар драматургы, артист, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1996).

Мин теге вакытта ук Зәкине[1] күреп сөйләшкән идем, ул «сигезенче саннан баса башларга кирәк» дип тә ычкындырган иде. Тик Марс[2] белән булган әңгәмә генә мине сагайтып калдырды. Ул «Әгәр роман басылып чыга калса, галимнәр арасында үзара сугыш китәр» дип курка икән. Сугышсыннар иде әле бер! Ичмасам азрак бер-берсенең күңел тузаннарын каккаларлар иде! Югыйсә әчеп, күпчеп беттеләр бит алар!

Шулай, егетем, син бер нәрсәгә игътибар итәсеңме? Менә журналда басарга проза юк бит... Союзыбызда фәлән кадәр язучы бар, дип мактануларның безнең өчен үтә зарарлы булуын бүгеннән күңелгә салырга кирәк. 150 дә 150, дип җиффәрәләр бит әле! Аның 62 се пенсионер, әллә нинди әфсеннәр укысак та, пенсионер прозаиклардан әллә ни көтәр хәлебез юк. Әле дә татар прозасы Әпсәләмнең[3] сыңар күзенә һәм сыңар бармагына калып бара, шуннан көтәбез бит! Ә биш елдан? Ун елдан? Картлар картая, урталар сөрлегеп, төшеп кала бирәләр. Әйтик: Барлас Камал, Эдуард Касыймов[4], атаклы «Җиз кадак» – Шамил Бикчуриннар[5] (аның «Каты токым»ы[6] – очраклы уңыш) үз сүзләрен тәмамладылар инде. Дөрес, Эдуард Касыймов Чаллы турында Кабан күле хәтле суын китереп аударачак, әмма аның киләчәк язмышы безгә бик мәгълүм! Прозаик дип союзга алган яшьләребездән дә

---

[1] Зәки Шәрәфетдин улы Нуретдинов (1921–1994) – шагыйрь, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе, 1971–1974 елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе.

[2] Марс Садри улы Шабаев (1933–2008) – шагыйрь, язучы, әдәби тәрҗемәче. Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1976), Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1984).

[3] Габдрахман Сафа улы Әпсәләмов (1911–1979) ул елларда инсульт кичерә. Ләкин иҗаттан читләшми. Тырышып-тырышып яза. Аның әлеге тырышлыгын легенда итеп сөйлиләр иде.– *Н. Гыйләҗева искәрмәсе.*

[4] Эдуард Салихҗан улы Касыймов (1930–1986) – язучы, фольклорчы.

[5] Шамил Мотыйгулла улы Бикчурин (1928–1991) – язучы, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1988).

[6] Ш. Бикчуриннның 1974 елда язылган романы.

әллә ни көтеп булмый, аларның берише – Рәфгать Кәрәми[1] һ.б. әллә кайчан «күңел пенсиясенә чыккан» ялкаулар ич!

Иң «яшь прозаикларыбыз» Миргазиян Юныс[2], Азат Ганиев[3]... Ике кеше. Инде әллә Әхәт Гаффардан[4] берәр нәрсә чыгармы дип йөргән идем, Габдрахман Минский[5] кебек монафыйкны остаз иткән кешедән ни өмет көтәсең?!

Бармакларыңны бөкләп уйлан әле, Мөхәммәт! Ничә кеше кала? Нурихан, син, мин, Гариф[6], Әхсән[7], азмы-күпме Рафаил Төхфәтуллин (аның да саулык чамасын беләсең!). Тагын кемне хәтердән чыгардым икән? Аз безнең сафлар, бик аз! Әле картлар нык кына бер рәт булып, бер-берсенә ябышып басып торалар. Алар егыла башласа ни булыр? Еникиләр[8], Бәширләр[9], Хөсниләр[10] киткәч (кызганычка каршы, атом бомбасы ясый алсалар да, гап-гади терек суын таба алганнары юк шул!) безнең сафларда ни калыр? Инде безнең барыбызга да илле тулып килә. Кайда кырык яшьлекләр? Утыз, егерме, димим?! Юк алар! Моның сәбәбе нәрсәдә? Фатих Әмирханның «татар баласы шул; авызы икмәккә туйгач тына» дигән кебегрәк, безнең халыкның асылын билгеләүче сүзләрен хәтерлисеңме? Икмәккә туйдык та ишәккә әйләндек кебегрәк килеп чыкмыймы? Безнең яшьләребез дә бик

---

[1] Рәфкать Кәраметдин улы Кәрамиев (1942) – язучы, ТАССРның (1989) һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре (2005).

[2] Миргазиян Мөхәммәтзакир улы Юнысов (1927–2014) – язучы, публицист, сынчы. Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2004).

[3] Азат Вәли улы Мөхәммәтганиев (1942–2012) – язучы.

[4] Габделәхәт Габдрахман улы Гаффаров (1948–2021) – язучы, драматург, публицист. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1998), Татарстан Язучылар берлегенең Ф. Хөсни исемендәге әдәби премия лауреаты (2008).

[5] Габдрахман Мөхәммәт улы Аллаһбирдиев (1906–1987) – язучы-прозаик һәм драматург.

[6] Гарифҗан Ахунҗан улы Ахунов (1925–2000).

[7] Әхсән Баянов (1927–2013).

[8] Әмирхан Нигъмәтҗан улы Еникиев (1909–2000).

[9] Гомәр Бәшир улы Бәширов (1901–1999).

[10] Фатих Хөснетдин улы Хөснетдинов (1908–1996).

туклар, аларның кәеф-сафа корып кына яшиселәре килә. Әдәбият исә — көрәш мәйданы, бәрелеш, кырылыш анда! Һәр язучының йөрәге вулкан, аның ни дәрәҗәдә һәм кайчан ата башлыйсын кем белгән? Шулай ук утырган эт биеклеге хәтле тауларыбыз да, усрак җылысы гына булса да чыгара торган вулканнарыбыз калмадымыни?!

Хат язар алдыннан бу фикерләр күңелемдә булды микән, синең якты исемеңне телгә алуга ук йөрәк зарымны да сөйлисе килеп китте, күңел моңымны да ачып ташладым...

Сүзем ул гына түгел иде... Син Роза Хафизованың[1] китабын бик мактап эчке рецензия язгансың, диләр. Кеше сүзе кеше үтерер, әгәр ялган сөйләсәләр, гафу ит. Әгәр хак булса... сиңа бик нык рәнҗиләр! Бик нык! Беренчедән, ул күте калынайган әби патша үзе яза алмый, аппаратында эшләгән кешеләр аның чүп-чарларын рәткә кертәләр. Шәхси секретарь итеп, ул ару гына теле дә булган Габделхай Сабитовны кешелектән чыгарды, шагыйрь Хәкимҗан Халиковны изде. Башка кешеләр дә аның өчен тырышып-тырышып язалар. Югары йортта кемедер бар аның. «Мине урынымнан ала алмыйлар!» — дип мактана икән хәзер һәм «Азат хатын» журналының редакторы булу турында хыяллана икән. Венераны[2] конкурент санап, Җәвад Тәрҗеманов исемле сакау ишәкне яллап, мине һәм «Яшь ленинчы»ны тешләтүче хәсис тә шул бит![3] Югары йортка да барган, Мәскәүгә дә шалтыраткан!

---

[1] Роза Сәет кызы Хафизова (1929—2005) — шагыйрә. 1962—1986 елларда «Ялкын» республика татар балалар журналында баш мөхәррир. ТАССРның (1974) һәм РСФСРның (1983) атказанган мәдәният хезмәткәре.

Бу хатта Аяз «Ялкын» журналы редакторы булып эшләгән Роза Хафизова турында язган. Ул елларда татар телендә чыга торган матбугат оешмаларының сүзенә нык колак салалар иде. Журналларның тиражлары зур, гонорарлары да мул гына булганга, редакторларына яраргa тырышулар күзгә нык ташлана иде.— *Н. Гыйләҗева искәрмәсе.*

[2] Венера Фәез кызы Ихсанова (1933—2019) — 1966—1977 елларда «Яшь ленинчы» газетының, 1977—1988 елларда «Азат хатын» журналының баш мөхәррире.

[3] *Кар.*: «Документлар» бүлегендә «Проза һәм балалар секцияләренең берләштерелгән утырышы Беркетмәсе (9 март 1978)».

Тырыша! Минем әсәремә тел тидергән өчен ачулана, димә, әгәр мин кабул итү комиссиясендә утырмасам, ул хатын әллә кайчан союзның идарә члены булып, члены белән безне шәп кенә кыйнаячак кеше иде! Бөтен кеше зар елаганда, нәфрәт елга булып акканда син... Син үзеңнең кем икәнлегең турында уйлыйсыңмы? Сиңа, миңа хата ясарга ярамый хәзер. Синең исем белән шундук сәүдә итә башлыйлар!

Менә шуны да әйтермен дигән идем...

Ә болай – монда шәп... Эшлибез, укыйбыз. Дөнья мунча кертә.

Казанга, дусларга сәлам. Кулыңны кайнар кысып, дусларча, АЯЗ.

Машинкада язган дип үпкәләмә, өйрәнелгән гадәт.

Г. К. ХӨСӘЕНОВКА[1]

18 ноябрь, 1976 ел. Подлипки

Гали Кәримович[2]!

Зарланырга уйламыйм, әмма зиһен таркау!.. Таркау! Фикерләр, җыела алмыйча, кайдадыр шунда баш очында гына йөриләр...

Менә чынлап торып әдәби эшкә тотынганга 20 ел тулып узды. 55 нең июлендә Казанга кайткан идем, берәр ел аңгы-миңге килеп йөрелде, 57 нең мартыннан «Чаян»да[3] эшли башладым, 56 нчының көзендә нык кына итеп яза башлаган идем инде.

Егерме ел... Дөньяви эшләргә байтак көч салынган: башта «Чаян»да, аннан «Азат хатын», актыктан «Казан утлары»нда эшләргә туры килде. Бер кисәк икмәк өчен «Җиңел кавалерия» составында «Татарстан яшьләре»нең[4] рейдларында йөрү

[1] А. Гыйләҗевнең Г. Хөсәеновка язган хаты язучының «Сайланма әсәрләр»енең 4 нче томына кертелгән (Казан: Татар. кит. нәшр, 2015, 272–274 б.)

[2] Гали Кәрим улы Хөсәенов (1909–2001) – театр һәм телевидение режиссёры, Тукай бүләге иясе.

[3] Иң борынгы сатирик журналларның берсе. Казанда 1923 елда татар телендә басыла башлый.

[4] Иҗтимагый-сәяси газета.

дисеңме, 5 тәңкә акча өчен шәһәр вытрезвительләреннән репортажлар оештырып йөрү дисеңме – бары да булды. Аннан, ике ел Мәскәүдә уку[1]. Әгәр мин бу дөньяда ни дә булса аңлыйм икән, мин тулаем Мәскәүгә бурычлы. Укуым бәхетле елларга туры килде: XX съезд... Ил кайнаган көннәр, без – шул кайнауның уртасында...

Егерме ел... Шул вакыт эчендә егерме пьеса язылган... Һәммәсе дә тигез, бер югарылыкта, димим. Сәнгать – спорт түгел, аның казанышларын метрлап үлчәп булмый. Валерий Брумель[2] генә ул, үз гомерендә бер югарылыкны ала да, гомере буе шуның даны җитә аңа! Сәнгатьнең казанышын бары тик заман сынавы гына билгели. Заман гына аның «иңенбуен һәм авырлыгын» үлчи ала! Егермесе дә калыр, дип өметләнмим, әмма «Киек Каз Юлы», «Җиргә тапшырылган серләр», «Эңгер-меңгер», «Өч аршын җир», «Кар астында кайнар чишмә»[3] һәм кайбер башка пьесаларым югалыр дип уйламыйм.

Егерме ел... Шул ара эчендә ун повесть иҗат ителгән. Арадан икесе әлегә татарча басылмады. «Өч аршын җир» журналда гына күренде. «Камыш бармак, көмеш тырнак»[4] русча китапларда гына дөнья күрде...

Егерме ел... Бер роман[5] язылган... Күпме хикәяләр... Мәкаләләр, рецензияләр, чыгышлар... Күпме укылган, фикер әйтелгән, бәхәсләр булып узган.

Егерме ел! Күпме кан коелган, күпме күз яше аккан, күпме тир тамган! Барысы да чиләкләп-мичкәләп үлчәнгән!

Сезгә вәгъдә ителгән «Без унике кыз идек»[6]... – егерме беренче пьеса. 1978 елда миңа 50 тула. Димәк, әгәр барысы да без теләгәнчә барып чыкса, бу пьеса минем 50 еллыкка чыгарга тиеш...

Сизәсезме, Гали Кәримович, хәлләр ничек?

---

[1] Югары әдәби курслар турында сүз бара.

[2] Валерий Николаевич Брумель (1942–2003) – җиңел атлетика буенча совет спортчысы.

[3] А. Гыйләҗевнең 1975–1976 елларда язылган комедиясе.

[4] А. Гыйләҗевнең 1969–1970 елларда язылган повесте.

[5] «Урамнар артында яшел болын» турында сүз бара.

[6] А. Гыйләҗевнең 1976–1977 елларда язылган пьесасы.

Юк, юк, мин юбилей дигәнне ишетергә теләмим. Юбилей – безнең сәнгатьтәге уен ул хәзер. Габдрахман Минский да юбилей уздыра, бүксә киереп телевизордан чыгыш ясый, «Ялкын» дип аталган чиле-пешле журналда оныгы белән рәсемгә төшә, Абдулла Сәләхетдинов дигән кеше, язучы булырга егерме ел омтылып, егерме адым да алга китә алмаган ишәк, аның «иҗаты»на багышланган кайнар речьләр сөйли, ә эшләгән эшләре уймакка да сыеп бетә! Безнең картлар юбилей-юбилей дигән уенның тәмен бик яшьләй татыганнар. 37нче елда талантларны һәм иңнәрендә башы булганнарны үтереп бетергәннәр, шуннан җыен әтрәк-әләм язучы булып калган. 50 яшьтән классик булып дәреслекләргә кереп, «бусы миңа, тегесе сиңа» дип чиннар бүлешеп яшәгән кешеләр һәммәсе хәзер 70кә җитте, аны узып китте. Биш ел саен, ун ел саен җыелыш җыеп, сорап, үтенеп җыйган телеграммаларны укып, куанышып яткан саңгырау торналар юбилей дигәннең дә дәрәҗәсен күптән бетерделәр. Мин – юбилейларның дошманы!..

Үземә 50 тула икән, бу үзаралай гына, дусларча гына әйтелә торган сүз. Мин үземә 40 яшь тулуны бик авыр кичердем... Бик авыр... Илле яшьне ничек кичерермен, әйтүе кыен. Әмма эш белән, нәтиҗәле эш белән билгеләп үтәсе иде... Мондый озын кереш сүзем, пьесам өлгермәс дигән сүзне әйтер өчен түгел, һич юк, киресенчә, безнең алда нинди авыр һәм катлаулы бурыч торганлыгын искәртеп китү өчен генә. Хыялым бер: сездә шәп итеп «Без унике кыз идек»не куясы иде. Тетрәтәсе иде залны бер! Мин мондагы санаторийдан әле өйгә кайтмыйм. 24 ноябрьдә Рузада семинар башлана. Мин шунда катнашачакмын. РСФСР Культура министрлыгы коллегиясе минем «Әңгер-меңгер»не русчага тәрҗемә итүне раслаган. Тур[1] тәрҗемә итәчәк. Без шушы якшәмбедә аның белән очрашып сөйләшәбез дә, ул 24еннән үк Рузага килә. Эшли башлый, мин 4 декабрьдә анда булырга вәгъдә иттем. Әнә шул академия театрында җан көеге булып калган пьесаны киләсе сезонда рус театрында[2] куйдырасы иде! Менә

[1] Валерий Петрович Тур (1940–2009) – сценарист, драматург, тәрҗемәче.

[2] В. Качалов исемендәге Казан Зур драма театры.

булыр иде ул юбилей-юбилей уйнап, халыкны алдап ятучы карт графоманнарга удар! Менә булыр иде ул «Кар астында кайнар чишмә» хакында кара гайбәт таратып ятучы Әхсән ишәк ибне ишәк Баяннарга җавап! Әмирхан Еники белән Ибраһим Газиның[1] юбилей уздырганнары юк. Булмады, булмас та. Аңа карап, аларның таланты кимемәдеме?!

Менә шулай, Гали Кәримович! Мин Әлмәт театрын яратам. Уйлый белә торган актерлары өчен яратам. Кешелекле мөнәсәбәтләре өчен яратам. Пьеса булачак. Без аны өлгертергә тиеш. Бер-беребезгә көч биреп яшик. Бергә эшлик. Җилгә каршы төкерергә ярамый, барыбер җилне җиңә алмабыз. Җилгә каршы давыл булып чыксак кына без аны җиңәчәк!.. Планнар менә шундый. Уйлар шулай...

Әлегә зиһен таркау... Бик таркау! Уйларны учка, йомгакка туплап бетереп булмый. Йа Ходай, бир мәдәт! Дусларга сәлам. АЯЗ.

Я. ЗӘНКИЕВКӘ[2]

22 ноябрь, 1976 ел. Подлипки

Хөрмәтле Якуб ага!

Бәйрәм алдыннан котлау хатыгызны һәм фотоларны алган идем, зур рәхмәт! Җитешеп үз вакытында җавап кына яза белмәдем, бердән, кадерле туганнар-кунаклар килеп төште, алар белән әвәрә килдек, икенчедән, 13 ноябрьдә Нәкыя абыстайга 40 яшь тулу көне иде, агайне җыелып, аны да нык кына бәйрәм иттек. Ә 14сендә, абыстайны «салып унга», Мәскәү якларына сәфәр чыгып киттек. Менә икенче атнабыз инде, Мәскәүдән ерак та түгел, урман-юллар арасындагы «Подлипки» дигән санаторийда дәваланып ятабыз. Мин монда 4 декабрьгә кадәр булам, аннан 17сенә кадәр Рузага китәм. Анда драматурглар семинары. Абыстай монда 9 ына кадәр була әле...

---

[1] Ибраһим Зарифулла улы Мингазиев (1907—1971) — татар совет язучысы, тәрҗемәче.

[2] А. Гыйләҗевнең Я. Зәнкиевка язган хаты язучының «Сайланма әсәрләр»енең 4 нче томына кертелгән (Казан: Татар. кит. нәшр, 2015, 272—274 б.)

Сез нихәлләрдә?

Эш барамы?

Зинһар, тагын бер нәрсәгә игътибар итегез...

Сез эш арасында «татар әдәбияты үрнәкләренә күз салам» дигән идегез. Мин үзем дә эш тукталып, сөрлегеп калганда, остазларның иҗатына мөрәҗәгать иткәлим. Үз тавышыңны тыңлап карыйсың да, алар белән чагыштырасың... Шунда күрәсең инде күрергә теләсәң! Сез бер нәрсәне онытып җибәрә күрмәгез: безнең татар прозасы хәзер – бик артта, бик примитив, күп сүзле, мәгънәсез проза. Картларның комы коелып беткән, алар билләре бөкерәйсә дә һаман бил бирмәскә маташып, иске кәвешләре белән һаман мәйдан уртасында уралалар! Фатих аганы гына алыгыз! Күпме чүп-чар чыгарды ул соңгы елларда! Исеме әдәбиятта күренеп торсын өчен генә күпме юк-бар хикәяләр бастырды! Квартир акшарларга килгән яшь кызларның ботларына карап та хикәяләр иҗат итте! Аның иҗатында заманны аңламау, күп сүзлелек элекке Фатих Хөснине басып, күмеп китте. Безнең әдәбиятта характерлар тудыру юк, характерлар! Милли характерлар! Бу җәһәттән русларның Шукшин[1] иҗаты бик характерлы. Шукшин бер чакта да акыл сатмый, надан икәнсең, аның хикәяләрен укыгач, акылны син сат! Ул характерлар тудыра. Ә характер бары тик тере кешедә генә була, һәм ул бары тик тере ситуацияләрдә генә чагылыш таба. Менә шуңа ирешергә тырышыгыз да сез! Сезнең кулда беркем дә күрмәгән чирәм җир – Себер татарлары тормышы. Әсәрне бизәрлек кенә тел үзенчәлекләрен дә сибеп бара-бара, фольклор, көнкүреш үрнәкләренә дә күз сирпеп барган чакта, сезнең әсәрнең кызыклы гына булып чыгуы бар бит! Тагын бер кат кисәтәм: кызыл авызлы була күрмәгез, кызыл сүзләр бүген ялыктырды, ун елдан соң аны ишетәсе дә килмәячәк!

Сез авторитет дип санаган татар язучыларының күбесе хәзер, һич шиксез, әдәбият үсешен тоткарлаучы таш кына бу-

---

[1] Василий Макарович Шукшин (1929–1974) – совет язучысы, кинорежиссёр, актёр, сценарист. СССР Дәүләт (1971) һәм Ленин (1976) премияләре лауреаты. РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе.

лып ятмыймы? Авторитетларга сукыр рәвештә иярә күрмәгез!

Характерлар тудыру ягыннан безнең Мөхәммәт Мәһди оста кеше, әмма соңгы романы[1] миңа бик ошаса да, аның зур бер җитешсезлеге бар: характерлар бер учак тирәсенә тупланмаган! Бер сызыкта, бер үк вакыйгаларга мөнәсәбәттә күренмиләр. Шуңа күрә аларның исемнәре бутала, зиһен таралып китә. Югыйсә, нинди кызыклы, заманча кешеләр галереясен иҗат итә белде егет! Шәп язучы!

Ашыкмагыз! Кат-кат уйлагыз. Хәзер башка кешеләргә укырга бик тырышмагыз. Безнең халык белсә дә, белмәсә дә киңәш белән тыгылырга ярата. Җырчыга җырларга беркем дә ярдәм итә алмаган кебек, ахыр чиктә, һәрбер иҗат эше —кешенең үз монополиясе. Минем дә киңәш бирергә тырышуым – бары тик сезне уйландырыр өчен генә! Үзегезчә эшләгез, үзегезнең эчке моңыгызга ышаныгыз!

Хушыгыз! Рәшидә ханымга, Әлфиягә[2] күп сәлам! Кулыгызны кысып, АЯЗ.

Т. МИҢНУЛЛИНГА[3]
7 декабрь, 1976 ел. Руза

Туфан!

Син үткән хатыңда: «Менә аралар якын булса да, хат язышып аралашабыз» дигән идең. Кызганычка каршы, без хатлар язышмыйбыз шул, сөйләшенгән сүзләр коридор диварларына, костюм җиңнәренә сеңә дә онытыла. Соңыннан күрәзәлек итеп баксана: «Ничек яшәгәннәр алар? Ягъни без. Нәрсә белән кызыксынганнар?» Бер шәһәрдә торганда да хат язышканнар элеккеге язучылар, запискалар җибәргәннәр. Без дә алардан ким түгел ләбаса, очрашканда базар бәяләрен, яисә хатын-кызларның калку күкрәкләрен сөйләшеп кенә вакыт үткәрмибез, үзебезчә дөньяның бар меридиан-

[1] М. Мәһдиевнең 1975 елда язылган «Каз канатлары» романы.

[2] Я. Зәнкиевнең кызы.

[3] А. Гыйләҗевнең Т. Миңнуллинга язган хаты язучының «Сайланма әсәрләр»енең 4 нче томына кертелгән (Казан: Татар. кит. нәшр, 2015, 272–274 б.)

нарын күңелебездә кисештерәбез. Кем аларны язып бара? (Мин кайбер урыннардагы «тыңлау аппаратлары» язып куйган сөйләшүләрне әйтмим, алары бар! Тик аларны да белми калуыбыз ихтимал бит!) Татар язучылары яшиләр, язалар, яналар, борчылалар, ә кем аларны белеп, барлап кала?

Хат язышырга кирәк! Дөрес, бәлки, безнең хатлар киң халык массасына кирәк тә булмас, әмма арадан берәүгә, кызыксынучан егеткә аларның кирәге чыгуы да бар. Табигатьнең кодрәте чиксез.

Менә мин тагын Рузада.

Эш сагынылган икән. «Эшкә тотына алырмынмы?» дип бик куркып килгән идем, кичә-бүген бик шәп эшләдем. Быел Рузада күңелсезрәк. Ниндидер төксе, мокыт халык җыйналган. Арада теге монафыйк Роман Солнцев[1] та бар! Күрешмибез, сөйләшмибез. Әле ярый Роберт Батулла[2] монда, аның белән сөйләшеп рәхәтләнәбез. Башкортлардан да Әхмәтшин[3] һәм Богданов[4] дигән йон төргәкләре килгән. Их, минәйтәм, бар иде элгәрге семинарларда егетләрнең асыллары!

Семинар 17 сендә бетә. Кичен банкет. 16 сында без төштән соң Культура министрлыгына җаваплы кешеләр белән очрашырга кайтабыз. Кичен автобус белән Рузага юнәләчәкбез. Аннан 17 сендә монда булып, 18 ендә янә автобус белән Мәскәүгә кайтачакбыз. Бәлки син дә 16 сында сәгать 4 ләргә министрлыкка килерсең дә безнең белән утырып та китәрсең? 17 сендә монда бергәләп ял итәрбез, 18 ендә бергә кайтырбыз. Инде 16 сында килә алмасаң, 17 сендә үзеңә җайлы вакытта кил. Мин монда «Туфан килә» дип әйтеп куйдым. Күңелле булыр иде, әй!

---

[1] Ринат Харис улы Суфиев (псевдонимы – Роман Солнцев, 1939–2007) – язучы. Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре.

[2] Рабит Батулла (Роберт Мөхлис улы Батуллин (1938) – язучы, җәмәгать эшлеклесе, публицист. ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1985), Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2004).

[3] Габдулла Габдрахман улы Әхмәтшин (1921–1984) – драматург.

[4] Фәрит Вәлинур улы Богданов (1932–2001) – башкорт драматургы, Башкортстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1992).

Иртәгә мин хатын янына кайтам, хатны шунда Мәскәүдә генә салырмын инде. Казаннан бер дә хәбәрләр алган юк, качаловчылар эшкә тотындымы-юкмы, белмим. Төннәрен уянам да, төн караңгылыгында чәч бөртекләремнең агарганын күреп-күзәтеп торам!

Рузада кар юк, кыш юк, төксе, мокыт, караңгы чырайлы кешеләр генә бар. Пьесалар да юк, диләр... Уңышсыз ел, уңышсыз вакыт...

Сине сагынам! АЯЗ.

М. ВӘЛИЕВКӘ[1]

1982 ел, 10 март, Казан

Хөрмәтле Мансур иптәш Вәлиев[2]!

Сезнең сораулыкны алдым. Игътибарыгыз өчен рәхмәт! Уйлашасы, киңәшәсе нәрсәләр байтак! Бәлки, җаваплар Сез теләгән тәртиптә булмаслар, алдан ук гафу үтенәм. Үзегез карарсыз.

Безнең әдәбият өчен җаваплы урыннарда утырган байтак җавапсыз иптәшләр тартай кебек һаман бер җырны тәкрарлыйлар: «Прозабыз үсә! Киңәя! Татар прозасының магистраль төп темасы эшкәртелә!» – диләр.

Хак! Кайбер кыйммәтле казанышларыбыз бар: М. Мәһдиев, Н. Фәттахларның[3] иҗаты һәрьяктан мактауга лаек, боларга Миргазиян Юнысның соңгы ике повестен – «Табу һәм югалту»[4], «Биектә калу»[5]ларны кушып җибәргәндә, соңгы еллардагы хәл ул кадәр үк хәвефле дә күренмәскә мөмкин.

---

[1] А. Гыйләҗевнең М. Вәлиевкә язган хаты язучының «Сайланма әсәрләр»енең 4 нче томына кертелгән (Казан: Татар. кит. нәшр, 2015, 440–466 б.).

[2] Мансур Хаҗи улы Вәлиев (1948) – язучы, әдәби тәнкыйтьче, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1989).

[3] Нурихан Садрилмән улы Фәттахов (1928–2004) – Татарстанның халык язучысы (1998), РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1978), Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1994).

[4] М. Юнысның 1979 елда язылган повесте.

[5] М. Юнысның 1983 елда язылган «Шәмдәлләрдә генә утлар яна» повесте.

В. Нуруллин[1], А. Ганиев, М. Галиев[2] исемнәренә дә татар колагы күнегеп килә. Ләкин ил югарылыгыннан торып карaганда, дөнья биеклегеннән менеп уйлаганда, хәлебез бик авыр, үтә аяныч! «Уртачалар» әдәбиятны күмеп китте, басыпкамап алды, «ярар әйдә!» дигән үшән татар шигаре белән дөньяга чыга торган әсәрләребез көннән-көн ишәя. Журналларда, нәшриятта редакторларның таләпчәнлеге кимеде, тәнкыйтьчеләребез дә «чины олы кеше шәп яза!» дигәнчәрәк эш итәләр. Без янәшәбездә бөек чордашларыбыз: Ч. Айтматов, В. Быков[3], Н. Думбадзелар[4] барын онытып җибәрәбез, җае килгәндә, аларга да күсәк күтәрүдән чирканмыйбыз, алдынгы әдәбиятларның казанышын күрмәмешкә салышабыз.

Рус әдәбиятының соңгы еллардагы казанышлары да безгә бөтен тарафтан үрнәк булып торырлык. Гадилеге белән чорыбыз кешеләренең җаннарын барыбыз аңларлык һәм уйланырлык итеп ачып салган тиңдәшсез зур талант иясе В. М. Шукшинны гына алып карыйк. Миңа калса, Шукшин Чехов[5], Буниннар[6] белән нәкъ бер дәрәҗәдә тора, аларның намуслы дәвамчысы, ныклы варисы буларак, рус совет әдәбиятына гаять кыйммәтле, үзенчәлекле өлеш керткән кеше. Баксаң, темасы да гап-гади, без табынып, алга сөреп йөртә

[1] Вакыйф Нурулла улы Нуруллин (1935) – язучы, тәрҗемәче. ТАССРның (1972) һәм РСФСРның (1985) атказанган мәдәният хезмәткәре.

[2] Марсель Баян улы Галиев (1946) – шагыйрь, прозаик, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1995).

[3] Василь (Василий) Владимирович Быков (1924–2003) – белорус язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе, Бөек Ватан сугышында катнашкан, капитан. Тоталитар режимга каршы булган әсәрләр авторы.

[4] Нодар Владимирович Думбадзе (1928–1984) – совет грузия язучысы. Ленин комсомолы (1966), СССРның Ленин (1980) премияләре лауреаты, Грузия ССРның Ш. Руставели исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1975).

[5] Антон Павлович Чехов (1860–1904) – бөек рус язучысы, дөнья әдәбияты классигы.

[6] Иван Алексеевич Бунин (1870–1953) – язучы, шагыйрь. Әдәбият буенча Россиядә иң беренче Нобель премиясе лауреаты (1933).

торган темалар сыман «олы» да түгел сыман. Әдәбиятның үзәген характерлар, кешеләр билгели! Һәм менә нәкъ шушы урында Шукшин йөзәрләгән-меңәрләгән мактаулы «чинлы язучылар»дан аерылып тора да инде! Шукшин безнең катлаулы һәм аяусыз чорның барлык каршылыкларын, төсмерләрен, күңел байлыкларын үзләренә туплаган катлаулы характерга ия гади кешеләрне җырлады. М. Мәһдиев, соңгы елларның иң көчле хикәясе итеп, мәрхүм Василий Макарович Шукшинның «Срезал»[1] хикәясен ала.

Гыйбрәтле үрнәк! Чорыбызны аңларга тырышып яшәүче талантлы авторыбыз белән килешми дә мөмкин түгел. Шукшин нәни генә бер хикәядә заманыбызның явызлыгын, демагогларның, тел белән бушка тегермән тартып йөрүчеләрнең, бу очракта Глеб Капустиннарның дөреслекне ничек итеп таптап китә алуларын тапкыр рәвештә язып калдырган! Хикмәт Капустинның фән кандидаты Журавлёвны мәсхәрә итүендә генә түгел, хикмәт авыл мужикларының Капустин яклы булуында, аның бушбугазлыгыннан соклануында! Укыйсың – гыйбрәт! Уйланасың, яшәү, тормыш турында кызыклы нәтиҗәләргә киләсең. Сокланасың, чөнки автор без күреп, килешеп йөргән тормыш күренешләрен, гадилекне сәнгать югарылыгына күтәрә алган. Ә чын сәнгать – дөнья турында хөкем ул. Шукшинның шушы бер хикәясеннән чыгып та заман турында олы йомгаклау фикере әйтеп була, хикәя яшәтә, көрәшкә дәшә.

Балтыйк буе халыкларының прозасын алып карыйк. Күпме гүзәл романнар, повестьлар, тапкыр хикәяләр туды ул халыкларда! Бер генә мисал. Латыш язучысы Андрис Якубанның[2] «Шул ук гүзәл йолдызлар астында»[3] исемле хикәясен укып таң калган идем[4]. Замандашларыбызның кайберләрендә аермачык ярылып яткан рух ярлылыгын чорыбыз фаҗигасе дәрәҗәсенә җиткереп язылган бу хикәядә нинди үзенчәлекле характерлар! Хоккей белән җенләнгән кешеләр

---

[1] В. Шукшинның 1970 елда язылган хикәясе.

[2] Андрис Якубан (1941–2008) – латыш язучысы.

[3] А. Якубанның «Под этими чудными звёздами» исемле хикәясе.

[4] Дружба народов.– 1976.– № 10.

стадионнарга агылалар, ә боз өстендә Анатоль Достоевский, Апполлон Энштейн, Райнис Упит, Моцарт Вилюман Васнецов исемле үгездәй егетләр ваемсыз гына кәшәкә сугалар. Ә тирә-якта, трибунада – чишелмәгән меңнәрчә проблемалар! Хикәя персонажларының исемнәренә генә игътибар итегез... Әйе, җиребез гүзәл, күгебез якты, шул ук гүзәл йолдызлы күк астында да буш күңел белән яшәп була икән, гомереңнең санап кына бирелгән кадерле минутларын гел юкка, кирәкмәскә исраф итеп яшәсәң дә гомер уза икән!.. Автор конкрет шартларда туган конкрет язмышлар аша борчыла, укучыны борчый, аның күңел тәрәзәләрен туктаусыз шакып торырлык мәсьәләләр кузгата. Сәнгать барыннан да элек битараф калдырмаска тиеш! Сәнгать алдамаска, юатмаска, йокымсыратмаска тиеш! Моның өчен беренче чиратта авторларның заманны аңлый алулары зарур, заман кешеләрен җитәкли алырлык көчле рухлы булулары зарур! Ә уртача иҗат кешеләреннән ни көтәргә мөмкин соң? Үзләрендә юкны алар әсәрләренә каян тапсыннар?! Балтыйк буе халыклары язучылары җитди күз белән үз тарихларына борылып карый алалар, бүгенге проблемаларын дөнья халыклары алдына хөкемгә чыгаралар, укып сокланасың, нинди кызыклы халыклар бар, нинди үзенчәлекле аларның горефгадәтләре, яшәешләре, дисең?! «Д. Н.»[1] журналында былтыр гына басылган Юозас Балтушисның[2] «Юзас турында хикәят»[3] исемле романын гына алып карыйк. Язучы оста кул белән милли характерларны – Юзас, Адомасларны, кайнар мәхәббәте өчен җанын куйган Каруселарны тудырган, аларга халыкның барлык гүзәл сыйфатларын ышанып тапшырган. Юзас, Каруселар хәзер, литва халкының тулы вәкаләтле илчеләре булып, илләр буйлап гизәләр, халыкларның бер-бер-

[1] Мәскәүдә 1955 елдан рус телендә нәшер ителә башлаган әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси «Дружба народов» журналы.

[2] Юозас Балтушис (1909–1991) – литва язучысы, публицист, сценарист. ЛитССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1954) һәм халык язучысы (1969).

[3] Ю. Балтушисның 1979 елда язылган «Сказание о Юзасе» романы турында сүз бара.

сенә ышанычларын ныгыталар, кешеләрнең күңел офыкларын киңәйтәләр.

Казах, кыргыз әдәбиятларында никадәрле якты исемнәр барлыкка килде! Революциягә кадәр язма әдәбиятлары юк дәрәҗәсендә булган халыклар, совет власте елларында үсеп, ныгып, дөньяның иң көчле әдәбиятлары белән беррәттән, бер биеклектән торып иҗат итә башладылар.

Татар әдәбияты – совет әдәбиятының алдынгы бер звеносы, аерылмас өлеше, без дә хәл кадәренчә халкыбыз исеменнән гомумсовет әдәбияты казнасына актив өлеш кертә барырга тиешбез. Татар әдәбиятының югары дәрәҗәдә яки уртачалар хәлендә булуы гомумсовет әдәбияты үсешен дә билгеле, һәм бу безгә, татар әдипләренә, искиткеч җаваплы бурычлар йөкли. Гомумсовет әдәбиятының югары дәрәҗәдәге авторлары белән тиң иҗат итү – безнең бүгенге иң кискен, иң авыр бурычыбыз. «Нация обязана сделать всеобщим достоянием то лучшее, что есть у неё... Преодолевая свои частные интересы, она посылает всему миру приглашение принять участие в празднике её духовной культуры». Бу гыйбрәтле сүзләрне 1916 елда Япониядә сәяхәттә йөргәндә Һиндстанның бөек улы Рабиндранат Тагор[1] әйтеп калдырган. Башка халыклар арасында таралган һәрбер шигырь, хикәя яки пьеса ул – татар әдәбиятының гына түгел, татар халкының да йөз аклыгы, мактанычы һәм горурлыгы. Бу җәһәттән Муса Җәлил[2] иҗаты безнең халыкны бер баскычка югары

---

[1] Рабиндранат Тагор (1861–1941) – күренекле һинд язучысы, композитор, рәссам. Әдәбият өлкәсендә Нобель премиясе лауреаты (1913).

[2] Муса Мостафа улы Җәлилов (1906–1944) – шагыйрь, Советлар Союзы Герое (1956). 1942 елда фашистларга әсирлеккә эләгә. Татар хәрби әсирләреннән торган яшерен төркемнең рухландыручысы була. Әлеге төркем кушуы буенча пропаганда эшен алып бару һәм татар әсирләрен «Идел-татар» легионына җәлеп итү өчен, немецлар тарафыннан оешкан «Татар арадашлыгы»нда эшли. М. Җәлил алар арасында мәдәни-агарту эшен алып бара. Гитлерчыларга каршы эшчәнлек алып барганы өчен, 1944 елда Берлиндагы Плетцензее төрмәсендә иптәшләре белән бергә җәзалап үтерелә.

күтәрде, милләтебезнең авторитетын арттырды, аның тарихи бердәмлеген ныгытты...

Әйткәнемчә, без бүгенгебез алдындагы бурычларыбызны тарайтабыз, үзебезнең тар мәнфәгатьләребездән чыгып, теге яки бу язучыны күтәреп йөргән булабыз. Җыелабыз да ел йомгаклары ясыйбыз, икешәр көн бәхәсләшәбез, Тукай клубына язучыларның талашын — кәмит карарга килгән тамашачылар алдында һаваланып, түш киереп, трибуна артларына менәбез, мактыйбыз, макталабыз, мактанабыз. Татарстан язучыларының корылтай-съездларында да олы сүзләр ычкындырырга кыенсынмыйбыз. «Әдәбият үсә! Без гел алга барабыз!» — дип, авыздан ут чәчеп шаулашабыз. Ә юбилейлар, юбилейлар!.. Алардагы төче мактаулардан язучыларыбыз яртышар ел махмырлап йөри!

Ә нәтиҗә?! Ә җимешләребез?! Кемдер тузга язмаган әкәмәтләрен укмаштырып язып куя да «Роман яздым! Менә дигән әсәр!» дип банкетлар уздыра башлый. Аларга тәнкыйть сүзе әйтеп кара син бүген! Шунда ук Ирек мәйданына, Югары йортка жалоба белән чаба башлыйлар! Тәнкыйть йомшак булу аркасында, бездә күп кенә язучылар үз абруйларын тиешле дәрәҗәдә аңлый алмыйлар.

Саный башласаң, күпме алар, әдәбият тагарагыннан тәмле ашарга яратырга өйрәнгән һәм өйрәтелгән бушбугазлар, эшкуарлар, тел белмәгән килеш телле булып кыланган саламторханнар!..

Гомумән, әдәбият үсү нәрсә ул? Аны ничек үлчәргә мөмкин?! Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Әмирхан, М. Галәү[1], Ш. Камаллардан[2] да алгарак китеп, биеккәрәк күтәрелүме, әллә аның билгеләмәләре бөтенләй башкамы?!

Минемчә, моны билгеләүнең бердәнбер туры юлы бар. Гасыр башында һәм урталарында Г. Тукай, Һ. Такташ, Ф. Әмирхан, М. Галәү, Ш. Камал, Г. Ибраһимов[3], М. Җә-

---

[1] Мәхмүт Галәветдин улы Мәрҗани (1886—1938) — татар язучысы.

[2] Шәриф Камалетдин улы Байгилдиев (1884—1942) — татар язучысы.

[3] Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов (1887—1938) — язучы, галим, дәүләт эшлеклесе.

лил, Ә. Еникиләр татар әдәбиятын күзгә күренерлек бер югарылыкка күтәргәннәр. Төрки халыклар арасында безнең әдипләрнең иҗаты һәрдаим үрнәк булып саналып йөргән. Моның бик күп якты мисалларын китерергә булыр иде. Бу әдипләребез, үз чорларының лаеклы уллары буларак, үз вакытларының җаваплы кешеләре сыйфатында татар халкының язмышын, гореф-гадәтләрен, моңын-шатлыгын, көрәшен, тарихын, өметен, батырлыгын һәм куркаклыгын талантлы әсәрләрендә беркетеп калдырганнар. Алар һәммәсе дә үз чорларының һәм татар халкының лаеклы уллары була алганнар! Ак йөз белән халыкка караганнар, халыкның күңел тирәнлегенә үтеп керә белгәннәр, заман бәйләнешләрен аңлаганнар, заман үсешен хәрәкәттә – кешеләр язмышында бәяли алганнар. Халык та аларны кабул иткән, үз яшәешен, үткәнен һәм киләчәген аңларга теләгәндә, Тукайга, Такташка мөрәҗәгать иткән. Чын әдәбият һәрчакта халыкның күңел көзгесе булып барган, халык әдәбияттан яшәргә өйрәнгән, алдынгы идеяләр яктылыгында тәрбияләнгән һәм тәрбия иткән. Хәзер без, әдәбият үсә, дибез икән, нәкъ менә шушы бөек исемнәр тудырган һәм үстергән якты традицияләргә тугры калуыбызны күз алдында тотабыз. Бүген басылып, халык арасына чыккан һәр юл, һәр шигырь куплеты буш урынга, вакуумга чыкмый, ул Тукай, Такташ, Җәлил, Ф. Әмирхан китаплары белән янәшә яшәргә чыга. Безнең бөек мирасыбыз белән бер үк хезмәтне күрсәтә башлый, бер үк изге бурычларны башкарырга тиешле булып чыга.

Бүгенгедән Тукай, Такташ, Җәлилләр белән янәшә куярлык күпме хәзинәбез калыр? Дөрес, китапларның язмышын, язучыларның көч-куәтен билгеләү хокукы киләчәккә бирелгән, әмма мәсьәләнең болай куелышы да безгә таләпчәнлекне йомшартырга хокук бирми, киресенчә, без әдәбиятыбызның үсеш югарылыгы өчен һәрчак сакта һәм көрәштә булырга бурычлы. Без исә соңгы вакытта таләпчәнлекне бик нык йомшарттык, үзебезнең әдәби мирасыбыз янәшәсенә заман сынауларын уза алмаслыгы бүгеннән үк мәгълүм булган байтак әсәрләрне куярга маташабыз, безгә хәзер Ф. Хөсни дә классик, Г. Минский да классик, гел очраклы кешеләргә бөек гражданинныбыз Г. Тукай исемен йөрткән

бердәнбер премиябезне бирәбез, мактаулы чуар ярлыклар ябыштырабыз. М. Ш. да[1] Тукай премиясе лауреаты, Д. В. тә![2] Без үз утрауларыннан башканы күрмәгән һәм белмәгән, булу ихтималларын башларына да китермәгән Блефуску[3] утравында яшәп яткан лилипутлар хәлендә калмадыкмы икән?! Аларда да бөекләр булган, адмираллар, акыл ияләре булган, ә Гулливер[4] килеп утрауга аяк басуга, нинди нәни һәм кеч-кенә булып калганнар алар! Әдәбиятыбызның бүгенге көнен күз алдына китереп, чак кына тукталып торыйк... Гулливер-лар – Ч. Айтматов, гасыр романы «Йөз ел ялгызлык»ны[5] иҗат иткән Габриэль Гарсиа Маркес[6], Н. Думбадзе, В. Быковлар янында безнең мактаулы Ш. Бикчурин, Г. Ахуновлар кем булып кала?! Ямьсез шапырынулардан гына торган «Йолдызлар калка»[7] исемле әсәрендә Г. Ахунов үзен Ч. Айтматов, М. Кәрим[8], Дж. Родариларның[9] дуслары сыйфатында бик нык күрсәтергә тырышса да, гади генә бер сорау аны сугып екмыймыни?! Дуслык берьяклы гына була алмый ич ул, Гариф! Әгәр син дус дип санаган кешеләрнең берәрсе, берәр урында, телдә яки басмада, «менә Казан дигән калада Гариф Ахунов атлы бик тирән акыллы, талантлы дустым яши!» дип

[1] Марс Шабаев турында сүз бара.

[2] Диас Назыйх улы Вәлиев (1938–2010) – язучы, драматург. ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1976), ТАССРның (1981) һәм РСФСРның (1983) атказанган сәнгать эшлеклесе.

[3] Дж. Свифтның «Путешествия Гулливера» романындагы Лилипутия дәүләте белән сугышкан империя.

[4] «Путешествия Гулливера» романының төп герое.

[5] Г. Маркесның 1967 елда язылган «Сто лет одиночества» романы.

[6] Габриэль Хосе де ла Конкордиа «Габо» Гарсиа Маркес (1928–2014) – күренекле Колумбия язучысы, журналист. Нейштадт (1972) һәм Нобель (1982) әдәби премияләр лауреаты.

[7] Г. Ахуновның 1980 елда язылган повесте.

[8] Мостафа Сафа улы Кәримов (1919–2005) – башкорт язучысы, драматург. БАССРның халык шагыйре (1963), Социалистик Хезмәт Герое (1979).

[9] Джованни Франческо Родари (1920–1984) – итальян балалар язучысы.

искәртеп китсә икән. Ә болай... «Без дә сөрдек!» дигән үгез мөгезенә кунган чебен!

А. Расих[1] үзенең бер чыгышында: «Безнең алга чыккан сөңгеләребез булмаса да, әдәбиятыбыз тере, зур һәм үсә!» – дип чыгыш ясаган иде! Ялгыш караш! Ялгыш кына түгел, зарарлы караш! Кардиограмма белән чагыштырып карасаң, кәгазьдәге сөңгеләр нәкъ менә йөрәк тибешен билгелиләр! Күрсәткечләрдә уклар булмаса, йөрәк тибүдән туктый!.. Әдәбиятның көч-егәрен инә кадәр ук атып йөрүче лилипутлар бер халыкта да билгели алмаган, әдәбият һәрвакыт югары талантларга мохтаҗ булган, югары талантларга аерым бер игътибар сораган. Югары талант ияләре генә әдәбиятның гомер озынлыгын, әйтергә яраса, аның өзелмәс мәңгелеген билгеләгәннәр. Без, юмарт кыланган булып, «һәммәбез тигез!» дип һаваланып, «всем по серёжке» таратып йөрүче аңгыра хуҗалар хәлендә яшибез. Әдәбиятның үсешенә тоткарлык ясау, талантлар белән талантсызларны тигезләп кую – талант ияләрен түбәнәйтүнең, аларны хәлсезләндерүнең бер ысулы бу. Г. Ахуновның Язучылар союзы рәисе буларак ясаган докладларын гына алып карагыз. Аныңча һәммәсе дә ал да гөл, алга барабыз да алга барабыз, артка борылып карарга да вакыт юк, һәркемнең әдәбиятка керткән өлеше тигезләшә, һәркем бер үк дәрәҗәдә мактала, беркемнең дә исеме саналмыйча калмый. Гарифның да, алдагы сайлауларны күздә тотып, һәркем алдында яхшы атлы буласы килә. Власть татлы шул, тәмле шул, аны һич тә кулдан ычкындырасы килми!..

Мин югарыда безнең үз арабызда шактый югары күтәрелгән «казанышларыбыз»ның ил күләменнән чыгып караганда нык ук мескен булып калуын язган идем инде. Мәскәү, Ленинградларда бара торган югары утырышларда безнең әсәрләр бик сирәк, анда да тематик яктан гына телгә алыналар. Сәнгать әсәре буларак, сәнгатьнең үсешен билгеләүче буларак, соңгы елларда бер генә әсәрнең дә телгә керә алганы юк. Заманында СССР язучыларының съездларында татар әдәбиятына багышланган махсус докладлар тыңланган! Махсус докладлар!.. Һич шик юк ки, мондый дәрәҗәне алу-

[1] Атилла Кадыйр улы Рәсүлев (1915–1996) – язучы. ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1981).

да прозабызның да өлеше керми калмый. Соңгы ике съездда (мин СССР язучыларының съездларын күздә тотам!) татар әдәбияты вәкилләреннән бер генә кешенең дә исеме залда яңгырамады! Бер генә исем дә! Менә ул темага гына өмет тотып, кысыр сыерга атланып сират күперен кичәргә йөз тотсаң ни килеп чыга! Кая ул Г. Ахуновның без мактап йөргән әсәрләре дә кайда ул Ш. Бикчуринның бик нык күтәрелгән романы?! Күтәрелде-бәрелде, [...] ярылды! Бармы алар, юкмы – съезд өчен, ил әдәбиятының яшәеше өчен барыбер!..

Эш нәрсәдә?!

Ни өчен илебездә иҗат өчен бөтен шартлар, мөмкинлекләр туган бер дәвердә, башка халыкларда әдәбият, сәнгать гөрләп чәчәк атканда, безнең әдәбият, аерым алганда, прозабыз, шулкадәр тешсез, йомшак һәм ябагалы булып калды әле?! Сәбәп нидә?

Бу кискен хөкемгә аңлатманы бер мин генә таба ала торган түгел, мәсьәлә артык җитди, үтә катлаулы. Анысын да әйтим, инде хәзер яшәп, иҗат итеп килә торган язучылар үз йөзләрен тулаем ачтылар, аларның көтелмәгән сулышлары ачылып, дөньяны шаккатырырлык әсәрләр яза алырлар, дип ышанмыйм. Без барыбыз да якты өмет белән киләчәккә, яшь иҗатчыларга текәлергә, аларга офыкның киң икәнен беренче адымнарыннан ук аңлатырга, алга омтылышның көндәлек бурыч икәнен даими сеңдереп торырга тиешбез. Мин җаным-тәнем белән ышанам, безнең халык – талантлы халык, Тукайны биргән милләт, әле алда кемдер килер дә халкыбызның Тукайлар күрә алган бөеклеген, Такташлар ачкан хис дәрьясын, Җәлилләр татыган батырлыгын, кыскасы, җирдәге һәр халыкка хас булган асыл вә гүзәл сыйфатларның безгә ят түгеллеген заманыбыз кешеләре аша, чордашларыбызның яшәеше аша киң меридианнарга алып чыгар! Шуңа ышанам да, шуны көтәм дә! Без, бүгенге әдәбиятыбызның намуслы вәкилләре, Г. Минский, Г. Гобәй[1] һәм шуның ише әдәбият эгоизмы белән яшәгәннәргә тиешле отпор биреп, яшьләребезне чынлыкта тәрбияләргә, ак белән караны аерырга яшьли өйрәтергә, әдәбият эшенең көрәш һәм батырлык икәнен

[1] Гариф Шакир улы Гобәйдуллин (1907–1983) – язучы, тәрҗемәче. 1950–1953 елларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе.

аңлата торырга тиешбез. Без бүгенгебезне һәм яшьләрнең башлангыч адымнарын ил күләмендә куелган таләпләрдән чыгып бәяләргә тиешбез. Ялган мактаулар яшьләрне адаштыра, яшьләрдәге сизгерлекне югалта, хисләрен тупасландыра һәм, нәтиҗәдә, соңгы елларда яшьләребездә дә урта һәм өлкән буыннар кабатлаган хаталар аермачык сизелеп тора. Алар өстән-өстән генә, бернинди күңел җаваплылыгы тоймыйча, салкын кан, суык акыл белән ни теләсәләр, шуны язалар. Сәнгать – күңел җимеше. Бөек Тукаебыз үзенең бер китабын юкка гына «Күңел җимешләре»[1] дип атамаган!

Менә мин әлерәк кенә М. Маликованың[2] «Табиплар» дип аталган романын укып чыктым. Романын, хөрмәтле Мансур иптәш Вәлиев! Бу романны укып чыккач, мин бик озак уйландым. Беренчедән, мине авторның үз-үзен тотышы сагайтты. Ул романын, һичшиксез, уңышлы дип саный, булачак тәнкыйть фикерләренә алдан ук әзерләнеп тора. Дөрес, автор әсәрен язардан элек үз көченә ышанып тотынырга тиеш, һәм ул шулайрак була да. Һәр әсәрне «булды, ниһаять, мин бу әсәремдә күңелемнең бар булганын ачып салам!» дип башлыйсың. Ләкин, тәмам иткәндә, күңел бушанып, тән тугарылып калганда, әсәрнең шәп булып чыгуына бик сирәк авторлар гына ышана. Блок[3] «Унике»[4] поэмасын тәмамлагач, «бүген мин гений!» дип әйткән. Пушкин[5] «Евгений Онегин»ның[6] соңгы ноктасын куйгач, «ай да Пушкин, ай да сукин сын!» дип, урындыктан урындыкка сикереп йөргән. Мондый очраклар тагын бардыр, әмма соңгы бит ябылганнан соң, авторның күңеле яңача газаплана башлый. Һәм мин әнә шундый газапларның яңасын татырга әзер торган

[1] Г. Тукайның 1911 елда бысылган китабы.

[2] Мәдинә Габделхак кызы Маликова (1935) – язучы, ТАССРның (1976) һәм РСФСРның (1985) атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан журналистларының Х. Ямашев исемендәге бүләге лауреаты (1980).

[3] Александр Александрович Блок (1880–1921) – шагыйрь, язучы, публицист, драматург, тәрҗемәче, әдәбият тәнкыйтьчесе.

[4] А. Блокның 1918 елда язылган «Двенадцать» исемле поэмасы.

[5] Александр Сергеевич Пушкин (1799–1837) – рус әдәбиятының бөек язучысы.

[6] А. Пушкинның 1823–1831 елларда язылган шигъри романы.

авторларга ышанам. Тәнкыйть йомшаклыгыннан бозылып өлгергән кайберәүләр үз иҗатларына гашыйк булып йөриләр. Һәм алардан әдәбиятка файдадан бигрәк зарар күбрәк тә була. Поза шәп, күкрәк киң, ә язылганы – ташкаүлчим! Г. Минскийдан башлап, бәләкәй авылның чиркәүләре кадәр гәүдәләрен туп-туры тотып, кысыр кәҗә имчәге хәтле иҗатларын селкеп әдәбиятның түренә уза алганнар азмы әллә бездә?! Болар һәммәсе дә язучыларның үз иҗатларын ялгыш аңлаудан килә. Ялгыш аңлау – үз иҗатың белән соклануга китерә, үз иҗатың белән соклану сукрайта, язучы исне дә, төсне дә аера алмый башлый. Таләпчәнлек, үзеңә һәм тиңдәшләреңә ышанычлы, гадел таләпчәнлек – менә нәрсә җитми безнең авторларга! Таләпчәнлек юк җирдә – кәсепчелек, алай гына да түгел, чеп-чи халтура үсә башлый. Кәсепчелекнең киңәюенә барыбыз да гаепле, шул җөмләдән мин дә! Күп әсәрләрне укырга туры килә: шунда еш кына, әсәрләрнең җитешсезлеген, шапшаклыгын билгелим дә... журналга «басарга!» дигән тамга салып илтәмен!

Кәсепчелек каян килә? Кем аны тудыра? Ничек итеп?!

Безнең әдәбиятта кәсепчелек аерата нык юл ярганга күрә, бу турыда ныклап сөйләшергә вакыт. Җавапсызлык, ваемсызлык аркасында без аны үзебез тудырабыз. Һәм менә шулайрак итеп тудырабыз.

Бездә, һәр әдәбиятта булган кебек, өметле генә башлап китеп, укучыны ымсындырып куйганнан соң, кинәт, чыгымчы ишәк кебек шып итеп туктап калган авторлар бар. Бар алар! Сөрлегәләр, туктап та калалар! Мондый очракта безнең хәсрәт тәнкыйтьчеләр каләм очы чәйнәп әй баш ватарга тотыналар! «Ай да вай! Ни булды? Нигә Хәниф Хәйруллин[1] тынды? Нигә Ринат Рәхимов[2] язмый? Шамил Шаһгалинең[3] пьесалары нилектән күренми?»; «Алда матур гына романнар биргән Эдуард Касыймовның соңгы әсәре үтә дә сыек иде, инде иң ахыргысы, Чаллы зонасындагы авыл хуҗалыгы эшчәннәренә багышланганы, кирпеч калынлыгы чеп-чи

---

[1] Хәниф Гыйздулла улы Хәйруллин (1931–1998) – язучы.

[2] Ринат Рәхим улы Рәхимов (1939–1984) – шагыйрь.

[3] Шамил Шаһгали улы Миңлегалиев (1920–1987) – драматург.

бәрәңге кәлҗемәсе булып чыкты түгелме соң? Ник алай? Ни үзгәрде? Язсын иде лә!»

Ә чынлап торып уйласаң, күз алдындагы фактларны бергә тупласаң, монда баш китәрлек, гаҗәпләнерлек бернәрсә дә юк. Язучы – табигать һәм тормыш тарафыннан әзерләнгән аккумулятор ул. Берәүләрне озакка җитәрлек һәм бик тыгыз итеп «тутырганнар», табигать һәм тормыш аларга бик күп, бик катлаулы һәм авыр, башкалар тырышып-тырмашып та чишә алмаслык серләрен ышанып тапшырган, аларны озак еллар дәвамында чыдарлык итеп көрәшкә әзерләгән. Икенче берәүләрдә исә мондый егәр аз яки бөтенләй чамалы. Табигать һәм тормыш андыйларга мыскаллап кына бирә байлыгын! Әйе, Сарман егете Хәниф Хәйруллин «Канатлар талмасын»[1] романын бирде. Әйбәт роман, кешелекле роман, тормышның без күз җиткерә алмаган тере бер почмагын кузгаткан актив роман. Хәнифнең үз сулышы белән кайнарланган юллар, аның дөньяга карашын төйнәгән образлар укучы күңеленә хуш килде. Сөендек! Ләкин, хәзер моңа һич шик юк ки, шушы китапка Хәниф бар булган күңел байлыгын, тормыш тәҗрибәсен, күзәтүләрен, зар-моңын, борчу-газапларын һәм өметләрен салып бетергән булып чыкты. Күңелендә туган уйлар нигезендә фәлсәфи һәм социаль чыгармалар – һәммәсе шушы бер әсәргә кереп беткәннәр. Хәниф барлык төзелеш материалларын «шушы йортка» урнаштырып, бер әсәрендә «тормышның иҗади отчётын» ясады. Дөрес, моннан соң ул «Картлык кемгә шатлык?»[2] исемле повесть язып бастырды. Бу әсәре исә аның «икенчел әдәби материал» иде, монда инде саф сулыш юк, һәммәсе таныш, без моңарчы күргән, башка әсәрләр аша белгән вакыйгалар бәян ителде. Бу повесть – кулы азмы-күпме шомарган, сюжет төзи белгән, фабуланы, образлар системасын сиземли алган грамоталы кешенең гади язмалары булып чыкты. Әсәр әдәби тормышыбызда аз гына да эз калдырмады, басылып чыкты да онытылды! (Юбилее уңае белән мактауларны мин искә алмыйм!) Инде килеп, Хәнифнең өченче повесте бернигә дә ярамады. Бусы көчәнеп, интегеп, төн йокысын кал-

[1] Х. Хәйруллинның 1974 елда язылган романы.
[2] Х. Хәйруллинның 1976 елда язылган повесте.

дырып, ни чарадан бичара, хөлдин-бөлдин язылган салкын, җансыз юллардан тора иде. Без бу уңышсыз туфракка төшкән гарип орлык турында Азнакайдагы конференция вакытында автор белән кат-кат сөйләштек, Хәниф үз җитешсезлеген аңлап, кайгырып: «Киңәшегезне бирегез, ничек коткарыйм бу әсәремне?» – дип, кат-кат үтенде. Әмма укыган кешеләрнең җавабы бер һәм туры иде: «Юк, әсәр барып чыкмаган, барып чыгарлык көчкә дә ия түгел...»

Хәниф Хәйруллинга «Канатлар талмасын»ы өчен рәхмәт. Ул, кеше, гражданин һәм әдәбият сөюче буларак, үз бурычын үтәде. Әдәби хәрәкәтебезгә мөһим һәм бик кирәкле әсәрне кертеп җибәрде. Язучы берчакта да үзе өчен генә, үз кәефе һәм мәнфәгатьләре өчен генә яшәми, аның һәр сүзе халыкның гомуми мәдәни байлыгына кушылып китә, әгәр һәр автор шул хәзинәгә өстәлерлек берәр генә әсәр иҗат итә алса да – бәхетле автор. Гомере буе шырдый-бырдый шигырьләр язып йөргән футурист Гадел Кутуй[1] «Тапшырылмаган хатлар»ын[2] язып исемен мәңгеләштергән. «Әниемнең ак күлмәге»[3], «Зөбәйдә – адәм баласы»[4] исемле классик пьесалар тудырган Шәриф Хөсәенов[5] соңгы ун елда бер юл да язмый икән, нигә аның якасына ябышырга?! Шәриф тә әдәбиятта үз бурычын үтәгән кеше. Табигать биргән талантын түкмичәчми югары дәрәҗәгә индереп, халкына кайтара алган җан. Олпат язучы, классик драматург. Үлмәс «Ак бүре»[6] әкиятен кемдер тудырган, «мин язучы, мин талант!» дип, халкыннан яд итүне даулап йөрмәгән. Сөя белгән икенче бер мәҗнүн гомеренең асыл мизгелендә «Гөлҗамал»[7] көен чыгарган, ул да, «мин җыр остасы, көйче!» дип, дан артыннан томырылып чапмаган. Шагыйрь, колхоз рәисе Ринат Рәхимовның дәрт-

[1] Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев (1903–1945) – татар совет язучысы, тәнкыйтьче, журналист.

[2] Г. Кутуйның 1935 елда язылган повесте.

[3] Ш. Хөсәеновның 1968 елда язылган пьесасы (беренче исеме – «Әни килде»).

[4] Ш. Хөсәеновның 1961 елда язылган пьесасы.

[5] Шәриф Нургали улы Хөсәенов (1929–1999) – драматург. ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1989).

[6] Татар халык әкияте.

[7] Татар халык җыры.

дәрманы дәфтәр юкалыгы гына бер китапка җитте. Асылда, Эдуард Касыймов та — бары тик бер китап авторы гына. «Кояш көн дә чыга»[1] исемле повесть белән ул әдәбиятта күренде. Әмма аның бу әсәре үзенең фольклор экспедицияләрендә очраткан сукыр музыкант турында юл очерклары гына иде. «Гомер ике килми»[2] романы авторның чын, кайнар хисле, дулкынландыргыч китабы булды. Әтисе сталинизм чорында һәлак булган Эдуард буынының фаҗигасен үз шәхесе аркылы биреп, ата-анасы, туган иле, чордашлары алдында гражданлык бурычын үти алды, әнә шул — үзе кичергән трагедия аны бер мәлгә язучы ясап торды, биеклеккә күтәрде. Аннан соңгы әсәрләре бу романнан күп кайтыш, фикер, уй ягыннан шактый чуалчык иде. Аның барлык әсәрләре дә кулына каләм тота белгән гади кеше язмаларыннан уза алмадылар, Эдуард үз темасын таба алмады, чөнки аның күңелендә, акылында андый тема юк иде. Язучы никадәрле әсәрләр язса да, асылда, аның үзе генә белә торган, үзе генә яна торган бер темасы була. Нурихан Фәттах — үз темасын һәм күңелен халык белән берләштерү юлын тапкан автор. Мөхәммәт Мәһдиевнең дә темасы ап-ачык, күренекле тәнкыйтьчебез Фәрваз Миңнуллин[3] аны, «яшьлеген сагыну» дип, бик тапкыр исемләде. Хәзер тәнкыйтьчеләр алдында зур, җитди бурыч тора. Мөхәммәт Мәһдиев яшьлеген сагынып, берникадәр кабаланып та, янып-яндырып та бер-бер артлы романнар, повестьлар яза икән, моның эчке серен дә ачарга тырышырга вакыт. Мөхәммәтнең соңгы елларда үз кишәрлеген — яшьлеген сагынуын тирәннән эшкәртә башлавы бер дә юкка түгел, талантлы кеше, бары тик үз җанын ачып салганда гына, тормышка турылыклы булып кала.

Макталган тагын бер романны — Шамил Бикчуринның «Каты токым»[4] романын мин берчакта да югары бәяләмәдем, алай да, чагыштырмача, бу әсәр авторның уңышы иде.

---

[1] Э. Касыймовның 1962 елда язылган повесте.

[2] Э. Касыймовның 1964 елда язылган романы.

[3] Фәрваз Мөхәммәдулла улы Миңнуллин (1934–1994) — әдәбият тәнкыйтьчесе, язучы, тәрҗемәче. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1984).

[4] Ш. Бикчуринның 1974 елда язылган романы.

(Зирәк кешеләр хәтерли булыр әле, Бикчуринның тутыкмас коралы – «Тальян гармун»ы[1] бар иде, ул, ике дистә ел, шул гармунын тартып, әдәбият мәйданында урын алып торды!) Тәнкыйтьче Г. Ломидзе[2] роман турында мондый фикер әйткән иде: «Роман татарского писателя Ш. Бикчурина «Твёрдая порода» не написан специально на интернациональную тему. (Әгәр шулай икән, аннан ни зыян булыр иде? – *А. Г.*) Интернациональный пафос в нём возникает словно ненароком как следствие пристального изучения писателем многочисленных сфер жизненных и человеческих «сцеплений» в действительности»[3].

Акның ак икәнен ышандырырга тырышалар икән, ак бик үк ак түгел икән, дигән фикергә киләсең. Ш. Бикчурин, нәкъ менә Ломидзе әйткәннең киресенчә, интернациональ дуслык турында роман язарга теләгән һәм шул максатына ирешкән дә. Бу абзацта мине бигрәк тә «ненароком» дигән сүз җенләндерә. Алай түгел шул, әгәр Ш. Бикчурин «ненароком» яза торган киң сулышлы, көчле рухлы автор булса, аның икенче китабы «Тирән катлам»[4] формасыз һәм сыек эчтәлекле булып чыкмас иде. Бу китапта инде бер генә төзек фикер дә, яңа уй да, язучының җанын ачып сала торган фактлар да юк. Бар да таныш, барысы да мең кат эшкәртелгән. Орлыгың яңа түгел икән, җирне мең кат эшкәртсәң дә, аннан уңыш алып булмый. Фикер орлыгыңның әле моңарчы шытып чыкмаган яңа, югары кондицияле булуы кирәк!

Без бушап, тыелып калган авторларны дәррәү көчләргә керешәбез, «нигә язмыйсың?» дип, әдәпсез сораулар бирәбез. Нәкъ әнә шул «дәррәү һөҗүм» тукталып калган авторларның буш күңелләрен иләс-миләс итә, алар язарга, көчәнеп булса да, кәгазь кыштырдатырга тотыналар. Хәтерегездәме? Тукай клубында, югары трибунадан торып, мөх-

[1] Ш. Бикчуринның «Тальян гармун» исемле музыкаль комедиясе (композиторы – Ә. Бакиров) өчен 1961 елда язылган либретто.

[2] Георгий Иосифович Ломидзе (1914–1999) – филология фәннәре докторы (1960), профессор (1965), тәнкыйтьче. Грузия ССРның атказанган фән эшлеклесе (1982).

[3] Вырастаться из единого корня // Октябрь.– 1976.– № 1.

[4] Ш. Бикчуринның 1980 елда язылган романы.

тәрәм язучыларыбыздан берсе Мирсәй ага Әмир[1]: «Яз да яз», дип әйтәсез, кайчан инде «язма!» дип, чын күңелдән киңәш бирә башларсыз икән?!» – дип, гадәтенчә, ярым шаяртып, асылда, бик җитди рәвештә җәмәгатьчелек һәм әдәбият әһелләре алдына кискен бер сорау куйган иде.

Кызганыч, әдәбиятыбызның намусы һәм вөҗданы булган Мирсәй ага үз тезисын конкрет мисаллар белән беркетмәде, әдәпне артыгы белән саклый торган иде, мәрхүм, авыр сүздән гомере буе сак булды, алай да аның кемне күздә тотуы мәгълүм иде. Кайберәүләрнең, йөгерә алмасалар да, һаман ярышларга катышырга омтылып, җитмәсә, марофон дистанцияләренә чыгарга маташып, соңгы ун ел дәвамында татар әдәбиятын нихәтле чүп-чар белән күмеп ташлаганын барыбыз да беләбез. Редакцияләр зарлана, өлкәннәр кулуарларда «без аңа әйтеп тә карадык инде, тукта, язма» дидек, дип, безләрне – урталарны юаталар. Ә ул «кайберәүгә» һаман мәйдан кирәк, исеме, нинди очрак белән булса да, матбугат битләрендә күренү кирәк... Ул үзенең түбән төшүен, көче беткәнгә кәсепчелек белән шөгыльләнүен эчке тойгылары белән сиземли, алай булмаса, яшьләрнең лыҗырдап торган әсәрләрен күккә чөеп мактап йөрмәс иде. (Аның Тукай клубындагы чыгышын хәтерлисез булыр?)

Без кәсепчелеккә килүнең төрле юлларына туктала алыр идек. Чөнки татар әдәбиятының бүгенге көнен билгели торган куркынычлы фактор ул – кәсепчелек. Кәсепчелек исә, исемлеләрнең элекке авторитетлы исеме белән уралып барса, әдәбиятка, бигрәк тә аның ныгып өлгермәгән яшь алмашына төзәлмәслек зарар ясый. «Әһә, әнә ич, өлкәннәр дә шундыйрак хикәяләр яза әле!» дигән сүзне ишетергә туры килгәне бар! Бер иш җилкуарлар, чиле-пешле әсәрләрен күтәреп, редакция бусагаларын тимер үкчәләре белән тибеп түбәнәйтәләр. Түбән бусага исә инде шуышып кына йөрүчеләргә, халтурачыларга да юл ача!..

Талымсызлык, таләпчәнлекнең йомшаруы мин алда көткән Тукайлар алмашының килүен тоткарларга мөмкин. Бу-

[1] Мирсәяф Мәсәлим улы Әмиров (1907–1980) – язучы, җәмәгать эшлеклесе. ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1945), ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1974).

сы инде тагын да куркынычрак. Безнең әдәбият бүген күңел аллаларына – Тукайларга, Җәлилләргә мохтаҗ. Менә өлкән буын вәкилләре берәм-берәм китеп торалар. Шушы елларда гына И. Гази, Г. Кашшаф[1], М. Әмир, Х. Туфаннарны озаттык. Йөзләре ак булган икән аларның! Вак-төяк ыгы-зыгылардан, хәзер безнең Язучылар союзында күзәтелә торган «төркемчелек»тән өстен булганнар икән алар! Гадел яшәгәннәр. Юк, «үлгән сыер сөтле була» дип сыктарга җыенмыйм, безнең Союз бик нык вакланды, чүпләнде, вак кешеләрдән ничек итеп олы әсәр көтмәк кирәк? Язучыларыбыз искиткеч надан, дөнья әдәбиятын гына түгел, мөгаен генә, бик күбесе татар әдәбиятын да укып бармыйлардыр әле...

Димәк, без һәммәбез дә – тәнкыйтьчеләр, әдәбият белгечләре, актив талант ияләре дә – каләмдәшләребезнең потенциаль мөмкинлеген бик яхшы чамаларга тиешбез! Мәсәлән, Эдуард Касыймов мисалында без, тырышып-тырышып, начар язучы ясадык, ә бик әйбәт фольклорчыбызны югалттык! Барлас Камаловның яшь чагын хәтерлик әле, нинди җитез, ут чәчрәтеп торган организатор, оештыручы, белгеч чыга иде аннан. Кандидатлык диссертациясен яклап, галим булып китә торган заманча мобильный егет иде бит. Ә без аннан язучы ясарга тырыштык. Шәп язучы да булып китә алырлык мөмкинлекләре бар иде! Мәсәлән, Зәки Нури соңгы елларда аның барлык әсәрләрен, редколлегия членнарын санга сукмый гына, үзе карап, үзе ипләп-сипләп журналда бастыра торды. Тикшерү актында күренгәнчә, аңа иң югары ставка белән гонорар да түләнеп килгән икән әле. Барлас Камалов запой белән эчә. Нигә эчә?! Эчендә җаны булган кеше юкка гына алкоголик булып китми, үзенең язучы түгеллеген Барлас та күңел түрендә сизенә торгандыр. Әмма ул моны бер чакта да икърар итәчәк түгел, мәгәр аның эчүенең сәбәбе – эчке көрәшенең нәтиҗәсе, дип беләм мин...

Әдәбиятта гомуми законнар юк, талант ияләренең, байтак «черем иткәннән» соң, Везувий вулканы күк уянып, дөньяны кубарып ташлавы да ихтимал. Мәгәр бер кагыйдә истә калсын: юк икән, юктан бар ясарга көчәнмик. Әгәр теге яки

[1] Миргази Солтан улы Кашшафетдинов (1907–1975) – әдәбият галиме, тәнкыйтьче.

бу язучы үз темасын тәмамлап, сандыгы бушап калган икән, тимәгез аңа, кылган гамәлләре өчен рәхмәт әйтеп, без аңа хөрмәт белән карарга өйрәник. Гамил Афзал[1] үзенең беренче классны сатирик шигырьләреннән соң балаларчарак, беркатлы лирикага бирелгән икән, аңа карап Гамил Афзалны әдәбият тарихыннан сызып ташларга мөмкин түгел! Аның хезмәте чиксез зур! Әмма язучыга, аның һәр адымына, иҗатының һәр баскычында дөрес бирелгән бәһа аңа ярдәм генә булачак. Кирәк чакта дөреслекне дә әйтә белергә ярыйдыр ла?!

Шагыйрь Равил Фәйзуллинның да «аккумуляторы утырды» дип ышанам. Зур талант иясе, безнең поэзиядә күзгә күренеп борылыш ясый алган шагыйрьнең дә «икенче сулышы» ачылмады, соңгы вакытларда ул кая барып бәрелергә белмичә талпына.

Без еш кына авторларның иҗат йөзен аларның тормыш юлыннан, шәхес үзенчәлекләреннән аерып өйрәнәбез, шул җөмләдән әдипләребезне, тарихыбызда «тапсыз эз» калдырган кешеләребезне дә, шәхес буларак, бөтен газаплары, каршылыклары, буталышлары белән халыкка җиткереп бетерә алмыйбыз. Безнең халыкны хәзерге хәлендә «хәтерсез халык» дип атар идем мин. Легендалар онытылган, риваятьләр онытылган, дин онытылган, батырлар онытылган, тарихыбызны анык кына берәү дә белми. Шуңа күрә әдипләребезгә, композиторларыбызга багышлап соңгы вакытларда чыга башлаган хатирә китапларыбыз да кысыр сыер җилене кебек сыек һәм нәни була. Карагыз инде шушы елларда басылып чыккан истәлек китапларын! «С. Сәйдәшев турында истәлекләр» китабы кайчаннан, сатылмыйча, китап киштәләрендә аунап ята. Чөнки андагы материаллар чынлыктан бик читтә, булганнары дулкынландырмый, кызыксындырмый, китапның начар аты халык арасында таралып өлгергән, шуңа күрә аны сатып алырга ашыкмыйлар! Әгәр Сәйдәш турында чын хатирәләр басылсамы?.. Кырылып алыр иде аны

[1] Гамил Гыймазетдин улы Афзалов (1921–2003) – язучы, шагыйрь. ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе (1977), Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1985), Татарстан Республикасының халык шагыйре (1992).

халык, кырылып! Һ. Такташ, Г. Ибраһимов, Г. Камалларга[1] багышланган истәлек китаплар да, ачлык елда туган балалар төсле, һаман кибет складларында боегып яталар. Чөнки бездә язучының шәхесен ачу традициясе юк. Ә башка милләтләрдән, әйтик, руслардан өйрәнергә, без артык һавалы халык, түргә узабыз да чабатаны түргә эләбез. Күрегез сез, рус халкы үзенең сөекле уллары Пушкин, Лермонтов, Толстой, Достоевскийлар хакында күпме истәлекләр калдырган. Бу истәлекләр, һичшиксез, халыкта үткәннәре өчен горурлык хисе тәрбиялиләр, аны яшәргә, уйларга, сөяргә өйрәтәләр! Иоганн Петер Эккерманның[2] «Разговоры с Гёте» китабын[3] телгә алмыйча узып китә алмыйм!..

Ярый, болары үтә бөек шәхесләргә багышлансын, ди. Үз көнебездәге мисалларга күчик: әле генә арабыздан киткән К. Симонов[4], А. Твардовскийларга багышланып, күпме кадерле истәлекләр барланып өлгерде инде. А. Штейнның[5] К. Симоновка багышланган истәлеге «Театр»[6] журналында басылып чыкты. Нинди кыйммәтле күзәтүләр, кадерле фикерләр җылытмый ул мәкаләне! 1980 елда Лениздат нәшрияты, рус шагыйре, Ватан сугышы батыры Сергей Орловка[7] багышлап, «Воспоминания современников»[8] исемле 17 табаклы

---

[1] Галиәсгар Галиәкбәр улы Камалетдинов (1879–1933) – күренекле татар драматургы, шагыйрь, журналист, әдәбият тәнкыйтьчесе, җәмәгать эшлеклесе.

[2] Иоганн Петер Эккерман (1792–1854) – алман шагыйре, әдәбият белгече.

[3] И. Эккерманның «Разговоры с Гёте в последние годы его жизни, 1823–1832» исемле китабы.

[4] Константин (Кирилл) Михайлович Симонов (1915–1979) – рус совет язучысы, Сталин (1942, 1943, 1946, 1947, 1949, 1950) һәм Ленин (1974) премияләре лауреаты.

[5] Александр Петрович Штейн (Рубинштейн, 1906–1993).

[6] Рус совет драматургиясе, театр, театр тәнкыйте турындагы журнал.

[7] Сергей Сергеевич Орлов (1921–1977) – рус совет шагыйре. РСФСРның М. Горький исемендәге әдәби премиясе лауреаты (1973).

[8] Кара: Воспоминания современников. Неопубликованное / сост. В. С. Орлова.– Л.: Лениздат, 1980.– 320 с.

китап бастырып чыгарды. Каләмдәшләре үз дусларының, арадан иртә киткән батыр шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү юлында мактауга лаеклы эш башкарганнар. Никадәрле сагыш, сагыну, аңлау һәм аңлату бар ул хатирәләрдә! Ә без?.. Без!.. Гомәр ага Бәшировның Х. Туфан матәменә багышланган мәкаләсе чыкты. Ничә еллар бергә иҗат иткән, янәшә яшәгән катлаулы язмышлы Хәсән Туфан турында кем-кем, ә Гомәр ага тарихи, олы сүзен әйтергә тиеш иде кебек. Ә ул «Хәсән балалар ярата иде... чәчәк түтәлләре арасында балалар белән әвәрә килә иде» дип белдерүдән ары уза алмады. Кайда Туфанның кичерешләре?! Егерме елга якын куылуда булган шагыйрьнең җанын аңлау кайда? Аларны Бәширов та аңлатмаса, кем аңлатыр?! Хәсән Туфанны шәхес буларак төптән аңламасак, аның шигырьләре бермә-бер кечерәеп, гадиләнеп калачак бит! Туфан турында төпле сүз – аңлату сүзе әйтелмәсә, Туфан иҗатының гомере озын була, дип, кем әйтә ала? Әдипнең иҗаты аның яшәеше, узган тарихы белән мең җепләр аша бәйләнгән.

Г. Тукай, Г. Ибраһимов кебек иң асыл затларыбызның тормыш баскычлары өстән-өстән генә өйрәнелеп килә, сәбәбе бер – без хәтерсез халык. Безнең төп милли сыйфатыбыз юк. Милләтне алга илтүче затларга үз вакытларында кадер-хөрмәт күрсәтә белмәгән кебек, алар вафат булгач та, без олы исемнәрне мәңгеләштерә алмыйбыз. Хатлар алышмыйбыз, истәлекләр язмыйбыз, көндәлекләр алып бармыйбыз. Хатлар алышсак – алдашабыз, истәлекләрдә кем кирәген хәтердән чыгармыйча икейөзлеләнәбез, көндәлекләрдә чынлыкны һәм тирәнлекне яшерәбез.

Җыеп кына әйткәндә, язучының биографиясе, аның көчле һәм йомшак яклары, күргән-белгәннәре, аралашкан кешеләре, мохите, дус-дошманнары, көндәлек гап-гади гамәлләре иҗат юлын өйрәнгәндә хәлиткеч роль уйный. Шәхес, сүтелеп, кеше буларак бушап беткәннән соң, берчакта да уңышка ирешә алмый, иҗат эшен дәвам иттерсә дә, мәгънәсез китаплар гына чыгарып торачак. Әдәбиятта ялган – бер көнлек, халтура – кыска гомерле. Безнең чордашлар аларны тырышып-тырышып озак яшәтергә тырышсалар да, барып чыкмаячак. Мәсәлән, Г. Әпсәләмовның вафатына кайчан

гына әле?.. Ә бүген... булганмы әдәбиятта Әпсәләмов, юкмы – аның бер эзе дә калмаган. Корама тел, ясалма стиль белән язган бу авторның бик күп романнары, шулай акрын гына, комга сеңгән су кебек сеңәчәк, югалачак. Ә ком өстенә иген чәчеп тә, йорт корып та булмый.

Онытканчы, тагын бер үтә мөһим буразнага – язучыларның үзаралый мөнәсәбәтләренә, русчалап әйткәндә, мораль климатка да аз-маз күз салып узыйк әле. Мин бу буразнаның күп санлы тармакларыннан бары тик берсенә – өлкәннәр белән яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләргә генә тукталып китәм.

Татар әдәбиятында озак еллар картлар булмыйча торды. Язучыларга картаерга тормыш үзе ирек бирмәде. Олы бер дулкын булып килгән язучылар төркеменең уйларга сәләтле, язарга талантлы, эшләргә оста алдынгы өлешен сталинизм чалгысы кисеп ташлады. Бөтен бер буын язучылар югалдылар: Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш[1], Ш. Усманов[2] һ.б., һ.б., һ.б. Шул заманнарда «Г. Тукай – буржуаз демократ!», «Ф. Әмирхан – буржуаз язучы!», «Дәрдемәнд[3] – череп таралган капиталист!» дип, тарихыбызны тәмам ярлыландырып бетерделәр. Тарихыбызда якты көзге булган олы затларның исемен мәсхәрә итеп, тере әдәбият мәйданына Хан Җәмил, Төхфәт Имаметдинов[4], А. Гомәр[5] кебек монафикълар, мөртәтләр хуҗа булып калды. Калган язучылар урталай сыналар. Үлем җәзасына хөкемен ишетеп, төрмәдән Мирсәй

[1] Фәтхелислам Закир улы Бурнашев (1898–1942) – күренекле татар шагыйре, драматург, публицист, тәнкыйтьче, тәрҗемәче.

[2] Шамил Хәйрулла улы Усманов (1898–1937) – татар совет язучысы, драматург, җәмәгать эшлеклесе.

[3] Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев (1859–1921) – шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, берничә алтын приискасы хуҗасы.

[4] Төхфәт Минһаҗетдин улы Имаметдинов – Татарстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы сәркатибе.

[5] Абдулла Закир улы Гомәров (1906–1974) – 1943–1957 елларда Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә эшли, 1953 елдан – «Совет әдәбияты» журналы җаваплы секретаре, 1963 елдан пенсиягә чыкканчы Язучылар союзында әдәби консультант булып эшли.

Әмир чыга, һәм «Агыйдел»[1] кебек гүзәл повесть, менә дигән сатирик хикәяләр язган кеше байтак еллар туктап тора һәм, җаны калтыраганга, әдәбиятта «уңай герой проблемасы» дигән лозунгка тагылып китә һәм бары тик герой гына яшәргә тиеш, дигән уй белән яши... «Кулак малае» булып кыйналган А. Шамов[2] бөтенләй шып туктап кала. Тагын бер юнәлешне ассызыклап узарга кирәк: утыз-кырык яшьләрдәге, әле иҗат принциплары ныгымаган, шактый куркак, шактый өркәк бер төркем язучылар әдәбият мәйданында батыр калалар – алар вакытлы матбугатта даими күренә башлыйлар, исемнәре әдәбият дәреслекләренә барып керә. Нәтиҗәдә әдәби сәләтләре шактый шөбһәле булган кайберәүләр дә бик иртә дан нурына манчылалар. Тукай мәктәп дәреслекләрендә теш аралаш кына телгә алынганда, Фатих Хөсни классик булып йөри иде. Фатих Хөснинең «Җәйге кичтә»[3] исемле үтә зарарлы, яшь буынны боза торган хикәясе ничәмә-ничә еллар татар балаларының башын бутап килде икән?! Мин соңыннан, атаклы немец язучысы Бертольд Брехтның[4] «Страх и отчаяние в третьей империи»[5] дигән бер пәрдәлек пьесасын укыгач кына, Ф. Хөсни әсәренең чын «кыйммәтен» белдем. Фашистик Германиядә дә балаларны ата-аналары өстеннән донос ясарга өйрәтеп килгәннәр икән! Ф. Хөсни шушы сыйфатны безнең алдынгы яшьләрнең шөгыле дип куәтләп яшәгән бит! (Ике әсәрдә дә балаларның өлкәннәр өстеннән донос ясаулары турында сүз бара!)

Кырык-илле яшьтә ансат кына әдәбият түренә менеп аяк бөкләп утырган бу төркем кешеләр шунда, түрдә, сакал сыпырып бик озакка кадәр утырдылар, олыгайдылар, күбесе олы була алмыйча картайды. Олылар белән яшьләр арасында бик озын дистанция булып торды, һәм без үзебездән өлкәннәр белән контактка керә алмадык. Миннән алдарак әдәбиятка кергән, тормышның алыш-бирешен, киселешләрен,

---

[1] М. Әмирнең 1935 елда язылган әсәре.

[2] Афзал (Афзалетдин) Шиһабетдин улы Шамов (1901–1990).

[3] Ф. Хөснинең 1936 елда язылган хикәясе.

[4] Ойген Бертольд Фридрих Брехт (1858–1956) – күренекле алман язучысы, театр теоретигы.

[5] Б. Брехтның 1934–1938 елларда язылган пьесасы.

бәрелешләрен һәрчакта да миңа караганда төплерәк аңлаучы, йөгерек фикерле, тапкыр телле һәм чак кына хәйләкәррәк Шәүкәт Галиев – минем чордашым, яшьтәшем – «без өлкәннәр ялгышын кабатламыйк, яшьләр белән аралашып яшик!» дип, гел әйтә килде. Мин бу акыллы сүзне берчакта да онытмадым, чөнки өлкәннәр белән контакт булмауның үземә никадәрле җәбер-җәфалар китергәнен гомерем буе татый килдем. Утыз пьеса язып, Нәкый Исәнбәтнең[1] минем хакта берәр сүз әйткәне бармы?! Р. Ишморатның[2] минем драматургия турында уй-фикере белән уртаклашканы бармы?! Безнең өлкәннәрдә һәрчак диярлек эгоизм чире бетеп җитмәде. Г. Гобәй, С. Баттал, Ш. Маннур кебек үтә чыккан эгоистлар яшьләр иҗатына битараф калып, аның үсүен тоткарлап та тордылар. Минем балалар өчен язган беренче әсәрем – «Дүртәү»[3] повесте балалар әдәбияты секциясендә тикшерелде. Секция җитәкчесе Г. Гобәйнең чыгышы әле дә истә! «Мин үзем повестьны укып чыкмадым, но аз-маз караштырдым. Минемчә, автор талантлы күренә!» – дигән иде ул! Мактыйм дип, кешене үтерү шулай буладыр инде ул! Эгоизм Ш. Маннур, Г. Бәшировта да бик көчле булды.

Өлкәннәрнең озак еллар буе дилбегәгә ябышып ятуы татар әдәбиятында бары тик куркаклар гына үстерде. Яшьләр кырыкка җитте, иллегә, алар һаман олыларның тешсез авызына карап тордылар, кыеп сүз әйтергә базмадылар. Куркаклык, кәсепчелек, талантсызлар белән талантлыларны бер чыбыркы белән куып йөртү – менә шушы сыйфатлар акрын-акрын гына татар әдәбиятын юаш мәхлукка әйләндерделәр. XX–XXII съездлар булып узды, совет әдәбиятлары өстеннән бәрәкәтле җилләр исеп узды, Ватан сугышы чорына башка милләт язучылары яңадан әйләнеп кайттылар,

[1] Әхмәтнәкый Сиражетдин улы Исәнбәт (1899–1992) – татар совет әдәбиятының аксакалы, танылган драматург, шагыйрь, язучы һәм галим. ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1968), ТАССРның халык язучысы (1986). ТАССРның (1957) һәм РСФСРның (1959) атказанган сәнгать эшлеклесе.

[2] Риза Фәхретдин улы Ишморатов (1903–1995).

[3] А. Гыйләҗевнең 1958 елда язылган хикәясе.

Бакланов[1], Бондарев[2], Быков, Симонов кебек кыю затлар Ватан сугышын өр-яңа аспектларда ача бардылар, ә татар язучыларыннан беркем дә ул темага әйләнеп кайта алмады. (Мин монда Ш. Рәкыйповның[3] документаль әсәрләрен, байтак язучыларыбызның Муса Җәлил темасын яктыртуларын искә алмыйм.) Беркем дә!

Рус язучылары үз милли характерларын эшкәртә башладылар һәм шул юнәлештә талантлы язучыларның олы бер отрядын илгә генә түгел, дөньяга чыгардылар. Без бу җәһәттә дә йоклый бирдек... Ярый әле Мөхәммәт Мәһдиев бу өлкәгә ныклап килеп керде. Тик бу турыда аз гына алдарак...

Менә ничә еллар әдәбиятка хезмәт күрсәтеп, том-том китаплар, пьесалар язып, Гомәр Бәшировтан бер сүз ишеткән юк, дип йөри идем, һич уйламаганда, иске журналларны актарганда, кызыклы бер отчётка юлыктым. «Совет әдәбияты»[4] журналының 1963 елгы 10 нчы санында, 157 нче биттә Гомәр аганың минем яманаты чыккан «Өч аршын җир»[5] повестена мөнәсәбәте басылып калган икән. Журналны тикшергәндә чыгыш ясап, мине пыр туздырган. Менә ул чыгыш.

«Икенче әсәр – А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир»е. Бу әсәр әдәби эшләнеше ягыннан да, көчлелеге ягыннан да башкаларга караганда яхшырак әсәрдер. (Кызганычка каршы, Гомәр ага әсәрнең көче нидә икәнен әйтми узган! – *А. Г.*) А. Гыйләҗев анда кешеләрдәге искелек калдыкларын күпертеп күрсәтергә омтылган. (Кайда күрде икән ул Мирвәли белән Шәмсегаянда искелек калдыкларын? Һм-м-м! – *А. Г.*) Авыл халкы – бик иркен күңелле, яхшы күңелле халык. Ул шулкадәр изге күңелле ки, хәтта ул мәкерле, күп әшәкелекләр эшләгән кешеләргә дә яхшы күз белән карап гафу итә ала. Менә шул нәрсә Шәмсегаян һәм Мирвәли образлары аша шактый тирән итеп бирелгән. Әдәби әсәрдәге теге яки бу герой әдәбиятка нинди яңалык алып килә, нинди яңа

---

[1] Григорий Яковлевич Бакланов (Фридман, 1923–2009).

[2] Юрий Васильевич Бондарев (1924–2020).

[3] Шамил Җиһанша улы Рәкыйпов (1929–2005) – язучы. РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1979).

[4] «Казан утлары» турында сүз бара.

[5] А. Гыйләҗевнең 1962 елда язылган повесте.

образ ул? Мин Шәмсегаянны шул яктан карыйм. Ул туган җирен, туган авылын бик нык сагына. Аның авылга кайтып үлүе туган илгә булган мәхәббәтен әйтеп бирә. Әмма, образ буларак, Шәмсегаян кем ул? Үзегезгә мәгълүм, әдәбиятта тарихи хакыйкать инде ул, безнең халык өч төрле басым астында яшәгән, изелгән, мескен хатыннар бик күп. Үзенең шәхси йөзе булмаган менә шундый хатыннар арасына кереп кала Шәмсегаян. Ул Мирвәлигә каршы бернәрсә дә әйтә алмый. Мондый образлар әдәбиятта бик күп. (Ишетәсеңме, Мансур дус! Ни ди татар әдәбиятының ул замандагы патриархы. «Бик күп!» – ди. Менә сиңа бәһа! Менә сиңа акыл! Менә сиңа әдәбиятта өлкәннәрчә алдан күрүчәнлек! Юк, әле моның белән генә сүз бетми. Тыңла! – *А. Г.*)

Үзенең шәхси йөзе булмаган менә шундый хатыннар арасына кереп кала Шәмсегаян. Ул Мирвәлигә каршы бернәрсә дә әйтә алмый. («Күп» сүзенең кабатлануына игътибар ит! – *А. Г.*) Хәзерге яшь язучы шуларны кабатларга тиеш идеме яки ул яңа образ тудырырга тиешме? Миңа калса, әдәбиятыбызны алга җибәрү өчен, яңа образлар тудырырга кирәк иде, образ буларак, ул нәрсәдер өстәргә тиеш иде. Мирвәлинең озакка сузылган уйланулары бик күп. Мирвәли үсәме, юкмы? Ул башта да, соңыннан да шул ук кире Мирвәли булып кала. Аңа бернәрсә дә йогынты ясый алмый. Авылдашлары аңа яхшы караган вакытта да, аның хисләре үзгәрешсез кала. Ул ерткыч та түгел, яхшы күңелле кеше дә түгел. Шунда ук бик артык төчеләнеп җибәрүләр дә бар. Мәсәлән, Шәмсегаян үзен бары тик каен белән нарат кочаклашып үскән җиргә генә күмәргә куша. Җитдилектән читкә алып китә торган нәрсәләр, ниндидер идиллия сизелә бу әсәрдә. (Ах, шул «ниндидер» сүзе! Күпме татар башын ашамагандыр ул утыз җиденче елларда! Әгәр бу бәя шул вакытта бирелгән булса, мескен Аязның башы да агач тагаракка тәгәрәр иде! – Бусы минем үз сүзем!) Теле әйбәт, автор мавыгып яза белә. Ләкин шуңа карамастан, художниклык көчен җитдирәк әйбергә сарыф иткәндә, Аяз тагын да җитдирәк әсәрләр иҗат итәр, дип әйтәсем килә».

Ху-уш, кодагый! Ата казың күкәй саламы? Соңгы абзац, типкәләп ташлаганнан соң, колак артын каз канаты белән

кашып көлдерергә маташу гына; шулай аңларга кирәк. Менә, аз да түгел, ким дә түгел, шушы чыгышны ясаган хөрмәтле аксакалыбыз Гомәр Бәширов. Беләм, син аны бик яратасың, хөрмәт итәсең, уеңнан кире кайтарырга җыенмыйм, әмма бер нәрсәне онытма: бу чыгышны ясаганда Гомәр Бәшировка 63 яшь булган инде! 63 яшь! Үзе артыннан кемнәр килерен бер дә уйламады микәнни ул?! Үз вакытында повестьны ботарларга дүрт яктан дүрт йөз шакал ташланганда, (башында Фикрәт Табеев тора!), Флүн Мусиннар бәгыремә кадалганда, мин бу сүзләргә игътибар иттемме-юкмы икән, хәтерләмим. Җыелышында булганмындыр, ул чагында, җыелышлар аша нидер үзгәртергә мөмкин әле, дип ышанып йөргән беркатлы дурак идем бит мин! Чынын әйтәм, Гомәр Бәшировның бу сүзләрне әйткәнен белми идем мин. Хәтерләмим[1].

Әле ул гынамы сиңа, әгәр сүз минем повесть турында гына барса, бүген ул җыелышны телгә дә алып тормас идем. Шул ук чыгышында Г. Бәширов әдәбиятны алга этәрүче, татар мәдәниятен ул көннәрдә югары күтәрүче сыйфатында икенче бер авторны – Гариф Галиевнең[2] исемен атый: «Мәсәлән, гади генә нәрсәләр турында сүз барса да, миңа Г. Галиев хикәяләре ошый. Соңгы елларда Г. Галиевнең колхоз темасына язуда активлашып китүе, минемчә, бик яхшы нәрсә. Ул үзенең шушы эшен киләчәктә дә шулай уңышлы (!!!) дәвам иттерсә, бик яхшы булыр иде!»

Бу сүзләр 1963 елда әйтеләләр! Сталинизмны тар-мар итеп ташлаган XX съездан соң… 60 нчы еллар башында!.. Колхоз, авыл хуҗалыгы темасына ул чакта Ю. Черниченконың[3] «Рус

[1] Аяз ул елларда, бер әсәрдән икенчесенә тиз-тиз күченеп, бертуктаусыз яза торган иде. Мин бу фикерләр язылган журналны яшереп куйганымны хәтерлим. Аяз пьесалар язу эше белән мәшгуль иде бугай. Әнкәй белән икәүләп шушы журналны күзәтеп чыктык та яшереп куярга булдык. Әллә кая түгел инде, билгеле, Аязның архивына. Үзе кайдадыр командировкада булгандыр. Болай да бик күп борчулар китергән әсәре тагын күңелен төшермәсен, дигән уйда идек без. Еллар үткәч булса да табып укыган бит шуны. Дөрес эшләгәнмен икән, дип уйлап куйдым. – *Н. Гыйләҗева искәрмәсе*.

[2] Гариф Закир улы Галиев (1903–1985) – язучы.

[3] Юрий Дмитриевич Черниченко (1929–2010) – совет язучысы,

бодае» исемле атаклы мәкаләсе[1] басылып, илдә киң таралган көннәрдә!

Татар әдәбиятында колхоз авылы темасын гомере буе изеп, мескенләндереп килгән, тәнкыйть күзеннән шыпан-шыпан гына читтә котылып калган уртакул язучы Гариф Галиев, 60нчы еллар башында, илдә колхозлашу, күмәк хуҗалык оештыру мәсьәләсенә яңачарак караш туып килгәндә, колхоз хәрәкәте, авыл турында нинди җитди сүз әйтә алсын?! 60нчы еллар башында әдәбиятның өметен Гомәр Бәширов менә кемдә күрә! Әдәбиятның уңышлы киләчәген әнә шул кешедән көтә! Кызык... Бу хәлләргә егерме еллар вакыт узгач, икенче бер аксакалыбыз Фатих Хөсни, шул ук Тукай клубы сәхнәсеннән торып, Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән...»[2] әсәрен тетеп ташлый һәм татар әдәбиятының киләчәге, өмете дип Нур Әхмәдиевне игълан итә!..

Менә өлкән буынның татар әдәбиятының киләчәген күзаллавы. Алар сызып биргән программа. Язучылар союзына кабул итү комиссиясендә әгъза вакытымда, Ибраһим Нуруллин да анда чакта, аның ике фикере бик нык хәтердә калган. Рәфкать Кәрами кандидатурасын тикшергәндә, Ибраһим: «Татар прозасының алдагы язмышын шушы кеше хәл итәчәк, ул аның иҗатына бәйле!» – дип белдергән иде. Мәрхүм Тәүфикъ Камалиев[3] иҗатын караганда: «Татар поэзиясендә җитди сүзне бары тик шушы егет кенә әйтә алачак!» – дип чыгыш ясаган иде.

Киләчәккә карау, киләчәкне аз булса да белергә, чамаларга тырышу – язучы-әдипләргә хас нәрсә. Иртәгәге көн турында чынлап торып кайгырта белү әдипнең күңел олылыгын билгеле. [...] Шуңа охшашлы чыгышлар, кешеләргә бәя биргәндә артык юмарт кыланулар әдәбият тирәсендә булган яшәүче һәм яшәячәк «толпаны» җылытып тора, аларны боза. Ә бездә андый ялгыш тәрбия бирүләр туктаусыз арта, ишәя тора. Мәсәлән, үткәннәрдән тагын бер мисал: Габдрахман

---

очеркист.

[1] Ю. Черниченконың «Русская пшеница» исемле очеркы турында сүз бара.

[2] А. Гыйләҗевнең 1972–1979 елларда язылган повесте.

[3] Тәүфикъ Салих улы Камалетдинов (1940–1980) – шагыйрь.

ага Әпсәләмов – иң тырыш, иң күп хезмәт куйган кешеләрдән берсе иде, әмма ул мактап, ул яклап чыккан авторлардан бер генә кеше дә язучы була алмады. Бер генә кеше дә!..

Гомәр Бәшировның ни өчен минем Шәмсегаяnnы яратмавының серен мин хәзер генә, олыгая төшкәч кенә аңларга тырышам. Н. Җиһанов[1] үзеннән башка бер композиторның да булуын теләмәде. Харис Якупов[2] талантлы художникларның һәммәсен куып бетерде. Яшьләрне инкарь итеп үз данын расларга тырышу татарларда модада булган! Гомәр Бәширов та талантлы кешеләрнең әдәбиятка килүен өнәмәгән булып чыга түгелме? Кешеләрдән күңел керен эзләмәсәм дә, нигәдер, бүген шулай уйлый башладым. Өлкәннәрнең кыланышын бары тик шулай гына кабул итә алам. Башкача ни сәбәбе булуы мөмкин?!

Тарихи шартларны да онытмыйк, халыклар төрмәсенең нәкъ уртасында, иң караңгы камерасында яшәгән татар халкының күңеле тарая төшмәдеме икән, дигән шик тә бар миндә. Тарлар без, татарлар без! Күремсезлек, тарлык – безнең милли сыйфатларыбызның берсе, кызганычка каршы, ул безнең картларга гына хас сыйфат түгел. Безнең Флүн Мусиннар тар күңелле түгелме әллә?!

Мондый тарлык бер безнең милләткә генә хас сыйфат та түгел. Мәсәлән, кыргызлар үзләре дә Чыңгыз Айтматовны ботарлап ыргытырлар иде. Бәхете – ул русча яза. Бәхете – аның беренче зур әсәрен Луи Арагон[3] күреп алган. Бәхете!

---

[1] Нәҗип Гаяз улы Җиһанов (1911–1988) – композитор, педагог, җәмәгать эшлеклесе. СССРның халык артисты (1957), ТАССРның Г. Тукай (1958), ике тапкыр II дәрәҗә Сталин премиясе һәм СССРның Дәүләт премиясе лауреаты (1948, 1950, 1970), Социалистик Хезмәт Герое (1981).

[2] Харис Габдрахман улы Якупов (1919–2010) – Россия Сәнгать академиясенең хакыйкый әгъзасы (1997, 1973 елдан СССР Сәнгать академиясенең мөхбир әгъзасы), РСФСРның, СССРның халык рәссамы (1963, 1980), РСФСРның, Татар автономияле совет социалистик республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1957).

[3] Луи-Мари Андриё (1897–1982) – француз язучысы, шагыйрь. «Халыклар арасында тынычлыкны ныгыту» халыкара Ленин премиясе лауреаты (1957).

Ә мин Чыңгыздан ким язар идемме әллә? Минем табигать биргән талантым анықыннан ким идеме әллә?!

Татарлар мине таптап узды.

Татарлар Казаннан торып Чыңгызны да буып атарлар иде, куллары җитеп үк бетми. Яхшылыкка куллары җитмәсә дә, начарлыкка кул сузучан ич безнең халык! Арадан берәвебез: «Чыңгыз Айтматов шул дәрәҗәгә җитте, зарарлы роман язды!» — дип чыгып әйтмәдемени? Үзе дә чеп-чи маңкорт булган [...] «Чыңгыз обывательләр романы язды!» — дип, адым саен бакырып йөрмимени?!

Шундый атмосферада әдәбият ничек үссен, ничек көчәйсен, ничек егәре арта торсын?!

Менә быел нәшриятта минем өч повесть бергә басылып чыгарга тиеш. Ул-бу булмагае дип, кан калтырап көтеп торам. «Өч аршын җир» повесте беренче мәртәбә китапта чыга! (Мәскәүдә чыккан русчасын санамаганда.) »Җомга көн, кич белән...», «Әтәч менгән читәнгә»[1] повестьлары да шунда. «Камыш бармак, көмеш тырнак» та[2] басылырмы әллә, дигән идем, анысы төшеп калды... Хәерле булсын! Әгәр «XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты» дигән төшенчә тарихта кала икән, Аяз Гыйләҗевнең бу повестьлары, һичшиксез, анда мактаулы урын алачак! Һичшиксез!..

Бераз мактандым (минем яшьтә мактану килешми, инде соң!), бераз моңландым (бу яшькә моңлану хас), бераз зарландым (иллене узгач, зарланасы да килә икән!), бераз уйландым. Озын яздым, кат-кат күчереп утырырга вакыт аз, сүзләр күплеген кичерерсең, Мансур дус. Инде шушы «гомуми сүзләр»дән соң синең сорауларга аз-маз конкрет җавап биреп карыйк.

Төп сүзгә күчәрдән элек Л. Н. Толстойның бер гыйбарәсен хәтергә алып узасы килә. Рус крестьян язучысы С. Т. Семёновның[3] җыентыгына кереш сүзендә ул болай ди: «Я давно уже составил себе правило судить о всяком художественном произведении с трёх сторон: 1. Со стороны содержания –

---

[1] А. Гыйләҗевнең 1979–1980 елларда язылган повесте.

[2] А. Гыйләҗевнең 1969–1970 елларда язылган повесте.

[3] Сергей Терентьевич Семёнов (1868–1922) – рус язучысы, «Лев Николаевич Толстой турында хатирәләр» авторы (1912).

насколько важно и нужно для людей то, что с новой стороны открывается художником, потому что всякое произведение тогда только произведение искусства, когда оно открывает новую сторону жизни; 2. Насколько хороша, красива, соответственна содержанию форма произведения и; 3. Насколько искренно отношение художника к своему предмету, т.е. насколько он верит в то, что изображает. Это последнее достоинство мне кажется всегда самым важным в художественном произведении». Шушы ук фикерне Л. Н. Толстой «О Шекспире и о драме»[1] дигән атаклы мәкаләсендә дә кабатлый.

Нинди гади һәм бөек хаклык ята бу сүзләрдә!

Нинди олы һәм чын таләп бар бу гыйбарәдә!

Һич шикләнмим, безнең бик күпләребез, шул җөмләдән инде танылган каләм ияләре дә үз язганнарына ышанмыйлар, алар вакытка һәм вакыт безгә җитәкче итеп куйган кайберәүләрнең тар зәвыгына ярарга тырышып кына язалар. Мин Гариф Ахуновка да ышанмыйм, эче тулы совет властена дошманлык булган Диас Вәлиевнең Ленинның яшьлеге турында яза алуына да ышанмыйм, ялган төчелек коллары булган беркемгә дә ышанмыйм. Чөнки алар әсәрләре аша миңа чынлыкны җиткерә алмыйлар, дөньяның чын асылын аңлау дәрәҗәсенә күтәрелмәгәннәр, ә безнең ныклап торып аларга отпор бирергә дә хәлебездән килми...

Бүгенге көн прозасыннан мин өч кешенең – Ә. Еникинең, М. Мәһдиевнең, Н. Фәттахның әсәрләрен генә кайта-кайта укыйм. Әсәрнең кыйммәте дә шуның белән билгеләнә дип ышанам; хәзерге заманда китап-журнал ташкыны арасында адашмыйча, кемдер үзенә ошаган язучыны табып ала, үзен газаплаган сорауларга җавапны, заманның чуалчык мәсьәләләренең чишелешен нәкъ менә шушы авторда күрә, китапны, бәс, шулай икән, аның авторын да үзенең пәйгамбәре ясый, аңа табына, гыйбрәт белән бергә эстетик ләззәт тә ала, аның башка әсәрләрен эзләп таба, кат-кат, кайта-кайта укый. Бары тик шундый укучысын таба алган, шундый укучыларның күңеленә хуҗа булып өлгергән китаплар гына киләчәккә калачак, шул китапларны тудыра алган чын талантлар гына татар халкының язмышын алда да бил-

[1] Л. Толстойның 1904 елда язылган мәкаләсе.

геләячәк. Кайта-кайта уку кешенең күңел үзгәрешләренең табигыйлеген сөйли, кеше яше үзгәргән саен үсә, үзгәрә, аның таләпләре төрлеләнә, әгәр ул шул төрләнгән таләпләренә җавап бирерлек китапка юлыкса, бу язучының да, укучының да бәхете дигән сүз. Ә. Еники, М. Мәһдиев, Нурихан Фәттах китапларында укыган саен, көн-ел үзгәргән саен, элек абайланмаган штрихлар, фикерләр табыла.

Бала чакның Тукае бертөсле иде, олыгайгач, Тукай да үзгәрә, катлаулана. Мәсәлән, балалар өчен язылган дип ышанып йөргән «Шүрәле» поэмасының үтә тирән политик әсәр булуын һәм безгә карап туры әйтелгән кискен хөкем икәнен мин бары тик олыгайгач кына аңладым. «Кем идек тә кем булып калдык!» дигән олы хөкемне яшь чагында, әлбәттә, аңлап булмаган.

Мин күңелдә берзаман урын алып та, гомер азагына кадәр күңелдән китми торган геройларны яшәргә хаклы дип саныйм. Дөрес, бу «геройлар»ның һәрвакыт кеше булмавы да ихтимал. Мәсәлән, Чыңгыз Айтматовның романындагы төлке, Каранар атлы дөя, Найман-ананың очып китеп кошка әйләнгән ак яулыгы – болар минем күңелемә гомерлеккә кереп урнашкан, минем бүгенге дөньяны аңларга ярдәм итүче көчле образлар. Геройлармы болар, юкмы – минем ул турыда уйлап караганым юк.

«Разведкага бару» дигәннән, мондый бер эпизод хәтергә төште. Газетада укыган идем. Бер класста укучылар Ватан сугышы батырының тормыш юлын өйрәнәләр һәм үзаралай мондый сорау куялар: «Әгәр син шушы батыр хәленә төшеп, ул кичергәннәргә дучар булсаң, нишләр идең?!» Әлбәттә, парта өсләре югары күтәрелгән куллар белән чуарлана, барлык укучылар диярлек, ярсып-кызып: «Мин дә нәкъ шулай булыр идем!» – дип, класс түшәмен шау-шу белән күтәрәләр... Ә арадан берәү, бер малай: «Юк, мин белмим, аның кебек батыр була алыр идемме икән?» – дип, шиген белдерә. Бөтен класс бу малайны мыскылларга, «куркак» дип көләргә тотына.

Ә мин бу очракта, һич икеләнмичә әйтәм, шушы куркак малай ягында. Үз күңелен чынлап торып ачып сала алу – бу да бик зур батырлык түгелмени?!

«Көчле шәхес, бай натуралар» җитеп бетми дигәнсез.

Мин бу сүзне аңламыйм да, кабул да итә алмыйм. Тормышның катылыгын татыган, сынауларын кичкән, арзан кызыктырулар барлыгын белеп торган килеш намусын саф килеш саклап кала алган кешеләр, сатмаган-сатылмаган кешеләр, иманнарына тузан кундырмаган затлар – көчле рухлы, бай натуралар түгелмени?!

Бар алар, бар! Безнең әдәбиятта да бар.

Миргазиян Юнысның «Биеклектә калу» повестенда 1945 елның язы сурәтләнә. Нәсел-нәсәбе гел сугышып, илләр талап кына яшәгән немец баронының крепость-йортында без яшь очучы Сәйрин Сәләхов белән танышабыз. Гап-гади авыл егете Сәйрин туган илен генә түгел, Европа халыкларын да фашизм коллыгыннан азат итүче батыр сыйфатында күз алдыбызга килеп баса. Фашист рыцаре, немец бароны һәм аларга каршы куелган татар егете Сәйрин. Крестьян баласы, авыл малае. Дистанцияләр һәр тарафтан бик ерак, ә шулай да барон өеннән чыгып качкан, Сәйрин – җиңүче!..

Каян килгән аңа батырлык сыйфатлары?

Нигә ул шулкадәр югары һәм олы җанлы кеше?!

Кем тәрбияләгән аны?!

Повестьның ахырында җан тетрәтерлек «Мөнәҗәт» дип аталган бүлек бар. (Кызганычка каршы, журналда ул бүлекне имгәтеп бетерделәр!) »Мөнәҗәт» аз сөйләп, күпне күрсәтә алуы белән күңелләрне тетрәтә. 1945 елның 9 маенда, сугыш тәмамланган көнне, улы Сәйрин фронтта һәлак буласы көнне, аның әнисе, күрше-тирә карчыкларын җыеп, мөнәҗәт укыта. Һәм шунда, гади татар карчыклары җыелып утырган табын тирәсендә, бөркет Сәйринне үстереп, очыртып җибәргән ояны күрәсең. Ул карчыклардагы күңел олылыгы, сафлыгы, бер-берсенә булган итагатьле хөрмәт, эчкерсезлек, горурлык борынгы фамилияләрне сөйрәп йөргән илбасарлардан өстен иткән икән!..

Бу гади мөнәҗәт уку бүлеге генә түгел, Сәйриннең батырлык чыганагын образлы итеп, югары сәнгатьчә итеп күрсәтү бүлеге иде. Безнең тәнкыйтьчеләр әсәрне күрә алмадылар, тирәнтен анализлап, укучының күңел офыгын киңәйтмәделәр. Әсәр басылды, күзгә күренде һәм онытыл-

ды. Ә ул безнең көрәш коралына әйләнергә хаклы әсәр иде бит!

Тагын нинди байлыкка ия булган геройлар кирәк сезгә, Ходаем?!

Образны «КамАЗ», автомашиналар белән бәйләп мәйданга чыгару – ансат юл ул, батырлыкны гадилектә күрә белү кыен. Батырлык ул – күңел ирегең, сафлыгын, горурлыгын саклап кала алу. Үлгәндә дә, гүрләргә кергәндә дә! Ә бу сыйфатларны бөек итә алу – язучының иманыннан, күңел ныклыгыннан гына килә.

Тормыш – язучының төп азык чыганагы. Язучының уе никадәр йөгерек, фантазиясе ничаклы бай, хыялы нихәтле киң булмасын, барыбер тормыш үзенең мең-миллион тырнагы белән язучыга караганда баерак була. Чын геройларны тормыш үзе тудыра һәм язучыга бүләк итә. Вакыйга, характерлар, образлар язучы күңеленә тормышның төрле төсмерләре белән килеп керәләр, ул аларны үз күңел байлыгы белән үстерә, фикере белән ныгыта, күңел серләрен әнә шул образларга тапшырып, әсәрләренә кертеп җибәрә...

Бүгенге тормыш таләпләре, нәкъ менә бүгенге фикер көрәшләре язучыны ерак тарихка да алып китәргә мөмкин! Бүгенге бик күп чуалчык мәсьәләләрне бары тик тарихка җентекле күз салып кына чишәргә мөмкин. Киләчәккә барыр юлларны бары тик тарихи фактлар аша гына билгеләргә мөмкин. «Итил суы ака торур»[1] исемле атаклы романыннан соң бик күпләр: «Нурихан Фәттах Болгар чорын өйрәнүгә бик күп көч салды, мөгаен, хәзер шул заман вакыйгаларыннан берничә роман бирер»,– дип ышанып көткәннәр иде. Ә Нурихан безнең эрага кадәр 209 елларга кайтып төште һәм «Сызгыра торган уклар»[2] исемле гүзәл романын иҗат итте! Гүзәл әсәр! Мавыктыргыч сюжет, тарихи характерлар, күпме яңа уйлар, яңа күзәтүләр!.. Күпләрне бу әсәр сискәндерде, «татарларның тарихы егерменче гасырның унҗиденче елыннан гына башлана» дип йөрүче кыска койрыкларны куркытты, роман редакция өстәлләрендә нәкъ биш ел сәяхәт итте!

[1] Н. Фәттахның 1960 елда язылган романы.

[2] Н. Фәттахның 1976–1985 елларда язылган тарихи роман-дилогиясе.

Биш ел! Без мәдәниятебез, халкыбыз алдында нинди олы җинаять ясавыбызны әле бүген бәяләп бетерә алмыйбыз! Нурихан кебек зур галимнең, талантлы язучының игътибарын биш ел буена шушы басылмаган роман алып торды, ул акчасызлыктан интекте... Асылда, романны бастырмас өчен, Зәки Нури белән аның шәкертләре бик күп көч түктеләр. Зәки Нури ишетә, белә... Кемнәрдер каршы... Киңәшә... Анда! Анда! Кул белән төртеп күрсәтергә ярамаган якта!.. Аларның тугры хезмәтчесе буларак Зәки Нури романны бастыра аламы соң?! Рәхмәт Ринат Мөхәммәдиевкә[1], егетлеге җитеп, романны чыгаруны үз өстенә алды. Редколлегия членнарының да бердәмлеген әйтеп узарга кирәк!..

Тарихны җентекләп өйрәнгән Нурихан Фәттах ни өчен безнең ерак бабайларны әллә кай гасырлардан эзләп тапты соң әле?! Әсәрдә телгә алынган Туман каган – борынгы язмаларда исеме сакланып калган беренче каган, Сөн дәүләтенең башы. Әгәр тарихи язмаларда Туман каганнан элгәрерәк конкрет берәр хан теркәлеп калган булса, Нурихан әсәрен әнә шул кешедән башлар иде! Чөнки ул татар халкының бүгенгесен тарихта конкрет эз калдырган каганнар белән теркәп кую бурычын куйган. Ул бүгенгебездән ерак тарихыбызга күпер салырга карар иткән. Булган бит, бар бит, безнең тарих Европага агылып килеп кергән монголлардан гына башланмаган, болгарлардан гына да түгел, әнә ул Н. Фәттах исемен халыкка чыгарган Туман каганнардан башланган. Туман каганның, Тәгин угланнарның исемен ишеткәч, миңа рәхәт булып китте. Югыйсә бик күпләр, хәтта аерым милләтләр, татар халкына тарихта урын калдырмаганнар иде инде. Кыпчакларны казахлар тартып алды, чувашлар – болгарларны! Укучылар бу романны зур кызыксыну белән каршы алачак, шикләнмим! Милли роман! Бусы да бик мөһим!

Әдәбият бары тик милли характерлар аркасында гына югарылыкка ирешә ала. Соңгы еллардагы илебез әдәбияты күгенә кадәр менгән авторларга гына игътибар итик: Ч. Айт-

---

[1] Ринат Сафа улы Мөхәммәдиев (1948) – язучы, әдәбият галиме, җәмәгать эшлеклесе. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1986), Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1993).

матов, Н. Думбадзе, В. Быков, Ф. Абрамов[1]... Болар һәммәсе дә үз халыкларының вәкилләрен нәкъ менә милли җирлектә калку итеп күрсәтә алдылар. Никадәрле байлык, салават күперендәге төсле елкылдаган төсләр бар милли характерларда! Әсәрдәге герой милли характер үзенчәлекләренә никадәрле бай булса, аның гомере шулкадәрле озын да булачак. Безнең әдәбиятның төп ялгышларыннан берсе шул (бу турыда кабатлап әйтәм!): без татар халкының милли үзенчәлекләрен белмибез, өйрәнмибез, аның эчке тирәнлегенә төшәргә тырышмыйбыз. Без рус та түгел, татар да түгел, чуваш та булмаган нindидер бер укмашкан сыйфатлы кешеләр турында язабыз. Әйтик, күп кенә авторларыбызның әсәрләрендәге геройларда нинди милли сыйфатлар бар?! Без типтәрләр, нугайлар, мишәрләр, керәшеннәр, башкорт татарлары барын бөтенләй хәтердән чыгарабыз, керәшен Гәрәй Рәхим[2] дә, тырышып-тырмашып, Казан арты татарларын язып маташа!..

Бу җәһәттән Мөхәммәт Мәһдиевнең иҗаты бөтен яктан мактауга лаек. Милләтнең җанын аңлый торган нечкә күңелле язучы! Милли характерларсыз әдәбият була алмаганны аңлаган чын художник! Гореф-гадәтләрне, милли мөнәсәбәтләрне, йорт-көнкүреш хәлләрен, кием-салымны, йолаларны тирәнтен белеп, әдәбиятта беркетеп калучы олы зат! Булды, саламторханнарга ияреп, мин дә Мөхәммәт Мәһдиевкә төртмә сүзләр әйтеп ташладым. Нигә, имеш, «сюжетсыз әсәрләр язасың?» Нурихан Фәттах Болгар дәүләте төзелә башлау чорыннан бик борынгы тарихка күпер салган икән, без: «Нигә алай?» – дип, гаепләү сүзе әйтәсе урынга: «Нурихан кебек олы талант иясе шундый адым ясаган икән, бу – юкка түгелдер!» – дип, аның шул адымына чын олы бәяне бирергә бурычлы. Мөхәммәт Мәһдиев кебек зур галим, искиткеч үзенчәлекле милли каһарманыбыз тышкы яктан сюжетсыз күренгән әсәрләрен бер-бер артлы бирә икән, безнең бурыч – моның нигез сәбәпләрен ачу. Серен укучыларга аң-

[1] Фёдор Александрович Абрамов (1920–1983) – рус совет язучысы, әдәбият белгече, публицист.

[2] Григорий Васильевич Родионов (1941–2021) – шагыйрь, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1985), ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1984).

латып бирү! Әллә, бик теләсә, Мөхәммәт әсәрләренә сюжет җебе үткәрә алмыймы?.. Аның беренче карашка сюжетсыз кебек күренгән әсәрләрендә нәкъ менә байтак күрә караулар күреп бетерә алмаган өзелмәс моң бар. Булды, без дә, Әби патша явыз теленә ияреп: «Мөхәммәт әсәрләре кипкән кукуруз бавырсагын хәтерләтә. Чәйнисең – авызда, теш арасында бар! Ашказанына гына берни төшеп җитми!» – дип сөйләнеп, аны раслап йөрдек. Көнчелек тудырган явыз фикер! Сугыштан соңгы чор кешеләрен, аларның кабатланмас рух төсмерләрен бөтен ваклыклары белән без Мәһдиев әсәрләрендә күрәбез. Халыкчан язучыбыз татар халкы вәкилләрен нәкъ булгандагы кебек итеп, төрле сфераларда, тормышның бөтен тармакларында милли характерлары белән бирә белде. Бу җәһәттән аның «Торналар төшкән җирдә»[1] исемле лирик документаль повесте аерата характерлы. Халык йөрәгеннән ургылып чыккан күпме милли моң бар бу әсәрдә! Гап-гади халык вәкилләрен нинди рухи югарылыкка күтәрү! Халыкның үзенә генә хас булган күпме эчкерсезлек, никадәр сафлык бар бу повесть юлларында! Без үз каләмдәшләребезнең иҗатына сокланып карау хисен югалтып барабыз, ахрысы! Мин бу әсәрне сокланып, эчке бер киеренкелек белән каткат укыйм! Кат-кат! Мин үзем өйрәнерлек урыннар табам, үзем белмәгән, белә алмаган искиткеч кешеләр белән очрашам! Повестьның һәр юлы минем күңелемнең иң тирән, иң нечкә урыннарына барып җитә. «Төлке уйный торган орлар...» бүлеген генә хәтергә төшерегез! Гаҗәеп, кабатланмас күренешләр, җырлар, моңнар бар бу юлларда! «Әя агач, яшең күпме?» бүлегендәге Хәдичәтти образын гына алыйк. Нинди гали рухлы, җор телле, белемле һәм саф күңелле хатын ул!.. «Әя агач, яшең күпме? Түгелгән яфрагың күкме?»

Аның авызыннан яңгыраган шушы хикмәтле сүзләр безнең рухны да баетмыймыни?!

Журналны укып ятканда, мәктәптән төпчек улым Рәшат кайтып керде. Күрә, күзләрем көлә, авызым ерык, керфекләрем сөенеч яшьләре белән чыланган...

«Нигә көләсең, әти?» – ди. «Болай гына...» – дип, журналны күрсәтәм.

[1] М. Мәһдиевнең 1979 елда язылган повесте.

Менә шушы өзекне укып ята идем.

«Менә көннәрдән бер көнне – җәйге җылы, чикерткәле кич – чык төшкән су буенда түгәрәк уен уйнаганда, минем белән янәшә баскан кызга игътибар иттем. Кунак кызы!

– Каян?

– Масрадан.

– Кемгә килдең?

– Сәрияләргә.

– Озаккамы?

– Бер кичкә.

– Синең белән якыннанрак танышырга мөмкинме?

Кыз кулын минем учтан ычкындырып читкә борылды, чәчен рәтләгәндәй итте. Аннан су һавасы кебек дымлы салкын тавыш белән болай диде:

– Анысын үзегез карыйсыз инде. Мин монда ярминкәгә килмәдем, товар күрсәтәсем юк...»

Артык бер сүз дә кирәкми, зирәк укучы шушы эпизодның «төбенә тоз сала» ала, кызның портретын да, чорның егетсезлек фаҗигасен дә, һәммәсен дә аңлап ала. Тупчындай киенгән, авылча мул күкрәкле, яше күптән җитсә дә, әле һаман парын таба алмаган бу кызның туп-туры сөйләшүе, аның дымлы салкын тавышы... Тулы бер чорны, яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ачып сала.

«Председатель Хайф», «Зөлфия» бүлекләрендәге нечкә юмор, диалогларда тере җиңеллек (җиләк вакытында Зөлфияләр капка төбендәге «оперативка»ны гына укы!), авыл-табигать күренешләрендәге кабатланмас матурлык – болар һәммәсе дә әсәрнең сәнгатьчә югарылыгын билгелиләр. «Пауал тегермәне» тирәсендәге трагедияләр, «Зәкәрҗан, алга!» бүлегендәге көлкеле маҗаралар – болар Мөхәммәт Мәһдиев иҗатының төп асылын билгелиләр: автор кеше күңелен аркылыга-буйга ачып сала ала, тормышның тере җәүһәрләрен – кеше характерларының төп үзенчәлеген – миллилекне тудыра белә.

Авызны ярым-йорты ачып, сүзләрне мыгырдап кына чыгарып, тарихи һәм милли әсәрләр тудырып булмый. Нурихан Фәттах белән Мөхәммәт Мәһдиев бүгенге көндә үз өсләренә иң мактаулы, иң авыр миссияне алып эш итәләр, алар совет

әдәбиятының бер канаты булган татар әдәбиятының — милли әдәбиятның җәүһәрләрен тудыралар. Игътибар итегез, алар икесе дә галим кешеләр, тарихны һәм этнографияне, фольклорны һәм лексиканы бик яхшы үзләштергән, күңелләренә сеңдергән кешеләр. Сүзләр алар — халык күңеленең ачкычлары, Н. Фәттах белән М. Мәһдиев — сүзләрнең кадерен белеп, бәһасен төшермичә яза белә торган язучыларыбыз.

Мин биредә бер-бер артлы өч кешенең исемен атадым. Гәрчә хатымның алдагы бер өлешендә «замандашларым үз сүзләрен әйтеп бетереп киләләр» дип зарлансам да, мин шушы өч кешегә чын күңелемнән ышанам, чорыбызның нурын алар алдагы буыннарга җиткерерлек әсәрләр язарлар дип өметләнәм. Язган кадәресе шундый ышаныч белдерергә куша.

Вакыйф Нуруллинның үзенә генә хас аһәңе, әсәрләренең кабатланмас ритмы бар. Үз аһәңе булу — язучы өчен зур бәхет. Күп авторлар үз аһәңнәренә ирешә алмыйча газап чигәләр. В. Нуруллинга чак кына кыюлык җитми, әмма ул — сәләтле язучы. Моңарчы да халык күңеленә якын байтак әсәрләр бирде. Соңгысы, «Һәлакәт»[1] исемлесе, халык арасында бик тиз популярлашты. Хикмәт кызыклы, маҗаралы сюжетта гына түгел, хикмәт чорыбызның яман бер күренеше — кешенең ваклана, җаны вагая баруында. Кешенең җанын ваклый-ваклый түбәнгә тәгәрәвен, ниһаять, рухи хәерчелеккә барып җитүен Вакыйф эзлекле итеп, җанлы картиналар аша дөрес тасвирлый. Мин бу повестьны бүгенгебезнең актив көрәшчесе итеп кабул иттем.

«Янәшә»[2] повесте язган Азат Ганиев соңгы биш-алты елда Габдрахман авылында өй салып ятты. Аның яңа әсәрен күргән юк. Әмма Азатның «Шәкүр карак» романын язуы килеп ишетелде. Күпләр аның бу эшен, романны укымаган килеш, «ахмаклык» дип кенә кабул итәләр. Ә мин аның җитди һәм кирәкле темага тотынуын сизеп торам. Дөрес, Шәкүр карак[3] — халыкның нәфрәтенә лаек булган, халкыбызның

[1] В. Нуруллинның 1983 елда язылган әсәре.

[2] А. Ганиевнең әсәре.

[3] Шәкүр Рәхимов (1861—1926) — XX гасыр башында данлыклы ат карагы, татар риваятьләре каһарманы.

йөзенә кара яккан шәхес. Әмма ат караклыгы безнең халыкта бик күптәннән яшәп килгән, ничектер, нинди сәбәпләр беләндер ярым легендар бер һөнәргә әверелгән. Бу җәһәттән уйланасы һәм бер фикергә тупланасы урыннар бар! Бәлки, Азат Ганиевнең эзләнүләре безнең өчен бик кызыклы булыр? Егет талантлы! Уйлы егет!

Марсель Галиев тә әле үз юлында ныгып, үз темасын раслап бетергән егет түгел. Әмма аның үзенчәлекле фикер сөреше, образлары, югары сәнгатьчә теле аңа өмет һәм ышаныч белән карарга куша. Ул үз стилен булдырып, аны кеше күзе төшәрлек итеп ачыклап гел алга бара, хикәяләре дә, хәтта газетада басылган очерк характерындагы материаллары да уй-фикерле була, ул тышкы эффектлар белән мавыкмый, кешенең бәгыренә үтеп керергә, аның күңел серләрен ачыкларга омтыла. Аның бу сыйфатларын үстерергә, егетнең дәртен куәтләргә генә кирәк...

Туфан Миңнуллин...

Нинди олы һәм затлы исем!

Татар әдәбиятының көчен-егәрен арттырган талант иясе! Әле 4 апрельдә генә «Диләфрүзгә дүрт кияү»[1] исемле спектакленең 400 нче куелышы булды. Әлмәт, Сибай театрларында куелу санын да кушсаң, татар сәхнәләрендә бу пьеса 1000нән артык барган икән! Олы хезмәт күрсәткән пьеса!.. Хәзер Академия театры – татар халкының университеты – 50 процент эшчәнлеген бары Туфан иҗаты белән генә бәйли. Мондый зур эшне бары тик олы талант иясе, армый-талмый халыкка хезмәт итүче Туфан гына башкара ала! Талантлы юморист шагыйрь, кыска юмор хикәяләренең остасы («Авыл апалары беләләр», «Майбәдәр батыр», «Хәсән – кирпеч» хикәяләренә күз сал!) Туфан Миңнуллин повесть язарга күптән кыҗрап йөри иде. Ниһаять, «Хәсән Вәгыйзович» повесте туды. Үзенчәлекле, усал повесть... Әгәр әсәр героеның прототибын да белсәң... гаҗәеп колоритлы кара фигура!.. Кара эчле кеше. Билгеле бер югарылыкка менеп җиткәч кенә, башкалардан үч алырга тотынган, беркемне дә аямаган маңкорт ул Хәсән Вәгыйзович! Тормыштан алынган, безнең арада яшәп килгән кешеләрнең иң әшәке сыйфатларын туплаган затны Туфан

[1] Т. Миңнуллинның 1968 елда язылган пьесасы.

усал итеп чыбыркылый, аны хурлык баганасына кадаклый. Сатира – әгәр аның уклары ышанычлы кул белән нәкъ менә мишеньнең алмасына атылган икән – төзәтү чарасы, безнең ышанычлы юлдашыбыз. Туфанның бу юнәлештәге беренче коймагы ук халыкка ярады, әсәр укыла, үз эшен эшли, бурычын башкара, безне уяу булырга чакыра...

Җиһангир, Бибинур, Хәйретдин агай, Фәүзияләр...

Минем соңгы елларымның юлдашлары...

Минем соңгы айлардагы тынгысыз төннәрем, чаптар аттай йөгерек уй-хыялларым. Алар – минем яшәешемнең серләрен дөньяга алып чыккан затлар. Мин үземнең «мин»емне аларга ышанып тапшырдым! Аларга! Шагыйрь әйтмешли, «сез үлсәгез – мин дә үләрмен!». Белмим, сез бу геройларны бергә җыеп, минем уйларымның бөтенлеген абайлый алдыгызмы икән?! Язучы, мең әсәр язса да, һаман үзенең бер кишәрлеген эшкәртә, үзенең төп сүзен табарга омтыла. Сез югарыда саналган әдәби геройларга чын тормыштан алынып, минем очеркка кереп киткән Үзбәк Саттаров[1], Шәфәгать Тәхаветдинов[2] дигән нефтьчеләрне дә кушып уйлагыз. Алар да – минем тормышка карашымны ачып салырга булышкан тере кешеләр. Әйе, бәлки, алар беренче карашка Мирвәлидән, Исхак, Гәрәйләрдән, ниһаять, Алимнардан аерыла да торганнардыр. Ләкин алар – һәммәсе дә «бер ата балалары»... Рухи сыйфатлардагы кайбер үзенчәлекне тормыш, еллар үзе билгели. Мине соңгы еллардагы кеше күңелендәге көтелмәгән үзгәрешләр сагайтты. Стефан Цвейгның[3] бер сүзен хәтергә төшерәсе килә: «Пора вдохновения революционного порыва, энтузиазма прошла, пришло время чиновников, карьеристов, деляг, стяжателей, казнокрадов и проходимцев»,– ди ул мәгълүм бер чорда, ачынып. (Өзек кул астымда юк, хәтердә калганча гына язам!) Безнең бүгенге хәлдә адәми затлар андый ук хәлгә төшмәсәләр дә, илебез тормышындагы социаль үзгәрешләр кешеләр характерын

---

[1] Үзбәк Газизович Саттаров (1922–1982) – язучы, танылган нефтьче.

[2] Шәфәгать Фәхраз улы Тәхаветдинов (1946) – «Татнефть» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (1999–2013).

[3] Стефан Цвайг (1881–1942) – Австрия язучысы, тәнкыйтьче.

кискен төрләндерде. Мин, «Урамнар артында яшел болын»[1] романының икенче басмасын әзерләгәндә, китапны башыннан ахырына кадәр өр-яңадан язып чыктым, яңарак фикерләр дә кереп китте. Әйтик, Әхәт Идрис белән әңгәмәсендә болай ди: «Кешенең тышкы кыяфәте ничек үзгәрми кала, диген син! Юкса аларның тешләре казык-казык, күзләре чынаяк-чынаяк, колаклары алып хәтле булырга тиеш иде ләбаса! Бармаклары, үзләренә таба кәкрәеп, ничек ярты метрга кадәр үсми диген?!»

Бу фикер 1970 елгы басмада юк, андый фикер ул елларда була да алмас иде, ә 1980 елгы китапка берсүзсез үтеп кереп китте. 1980 елдагы җан авазы иде бу сүзләр! Чөнки замандашларыбыз малтабарларга, җансатарларга әйләнеп беттеләр. Сатлык Иудалар «конвейерга куелгандай»[2], кардәшләребез бер-беренең туганлыгын онытканда, квартиралар кыйммәтле келәмнәр, ялтыравыклы савыт-сабалар белән шыплап тутырылганда, йортларда тере кеше җанына урын калмаганда, машиналы кешеләр бары тик машиналы кешеләр белән генә аралашырга омтылганда, һәр авылда учётка алынган алкоголикларның саны дистәләр белән генә саналганда (соңгы командировка мәгълүматлары: атаклы Бигеш авылында учётка алынган 30 алкоголик булса, Җәлилдән ерак та түгел Кармалы совхозында 60 эчкече бар!), күңел яхшылыкны, кешеләр арасындагы җылы, туганнарча мөнәсәбәтләрне юксына. Бәлки, әнә шул сискәнүләр, тетрәнүләр тудыргандыр Бибинур белән Хәйретдин агайларны?!

Тормыш үзгәрешләре берчакта да язучы күңелендә эзсез калмый. Нефтьчеләрдән бер мисал аласым килә. Нефть тимер трубалар буйлап ага. Нефть катнашкан су иң астан, шыпырт кына, нефтькә ияреп бара. Бүген ага, иртәгә ага һәм, трубаның иң астын уеп, бәләкәй генә улак ясый. Үзенә махсус улак! Әнә шул тозлы, реагентлы зәһәр су ясаган улак кебек, тормышыбызның ямьсез күренешләре язучы күңелендә дә эз сыза, гел борчып тора, бимазалый. Тормышның ямьсез күренешләре – язучы намусының чире ул. Язучы

[1] А. Гыйләҗевнең 1968–1969 елларда язылган беренче романы. Беренче басмасы 1970 елда басылып чыга.

[2] Бакланов Г. Меньший среди братьев // Д. Н. – 1981. – № 6.

аларга каршы көрәшкә күтәрелергә тиеш! М. Мәһдиевнең сугыштан соңгы кытлык, авыр еллардагы намуслы, риясыз татар кешеләренә дан җырлап чыгуы да бер дә юкка түгел! Тимер трубаларны нефть тишми, нефть туздырмый, нефть кенә акса, трубалар егерме елга чыдый, әнә шул приборлар да барлыгын абайламаган зәһәр су трубаларны дүрт-биш айда эштән чыгара, тишә һәм тишектән... нефть ага, нефть!..

Әдәбиятның үсү язмышы, киләчәге, аның дәрәҗәсе конкрет кешеләрнең конкрет эшчәнлегенә, иҗади атмосферага да бәйләнгән. Татар әдәбиятының язмышы Туфан Миңнуллин, Илдар Юзеев кебек талантлы драматурглар кулында. Аның язмышын билгеләүдә Н. Фәттах, М. Мәһдиев, М. Юныс, В. Нуруллин, М. Галиевләр дә зур роль уйнаячак...

Драматургиядә өметле иптәшләребезнең тулаем бер «алае» эшли (Нуриханча әйтсәк!). Р. Хәмид[1], Ю. Сафиуллин, Ә. Гаффар, Р. Мингалим[2], Ф. Садриевлар[3] – шактый үзенчәлекле, кызыклы кешеләр. Шагыйрьләребез арасында да кызыклы гына исемнәр яңгырап китә. Ләкин, минем бүгенге фикеремчә, бездә шигърият – иң артта калган жанр. Нишлисең, мин шулай уйлыйм.

Күргәнеңчә, мин татар әдәбиятының, башлыча прозаның нилектән шулкадәр аяныч хәлдә булуын үземчә ачыкларга тырыштым. Әгәр без Н. Фәттахны биш ел буе бастырмыйча яткырабыз икән, бу – шул аяныч хәлне тирәнәйтү! Әгәр без Миргазиян Юнысны журналда имгәтеп чыгарабыз икән, бу да шундый ук хәл! Әгәр без Мөхәммәт Мәһдиевне усаллар

[1] Ризван Мирхәбибулла улы Хәмидуллин (1941–2017) – драматург. Республика яшьләр оешмасының М. Җәлил исемендәге премия лауреаты (1984), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1991).

[2] Рөстәм Гали улы Мингалимов (1937–2014) – шагыйрь, драматург. ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1987), Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2005).

[3] Фоат Миңлеәхмәт улы Садриев (1941) – язучы, драматург. ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1991), Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт (2010) һәм Татарстан Язучылар берлегенең С. Сөләйманова исемендәге әдәби (2006) премияләре лауреаты.

авызына тыныч кына ыргытабыз икән, бу да җинаять! Артта калуыбызның бик күп объектив һәм субъектив сәбәпләрен табып була, әмма аңа карап, безнең хәл җиңеләйми. Җиң сызганып эшкә тотынырга вакыт. Әсәрләребезне русчага тәрҗемә итү язмышын саф күңелле кешеләр кулына тапшырып кына, без хәлебезне үзгәртә алабыз. Долой татарлыкны, тарлыкны!..

Мансур дус! Син сорауларыңны «Геройлар һәм проблемалар» дип атагансың. Синең сорауларга җавап булгандырмы-юктырмы – белмим. Татар прозасы турында башкача да уйлый алмыйм. Минем фикерләрнең кайберләре белән килешмәссең дә, ышанам. Ләкин аларны белеп тору сиңа – акыллы һәм сабыр тәнкыйтьчегә, сәнгатьне чын күңеленнән аңлаучы, сәнгатьтә төрлелекне кабул итә алырлык күңел көче булган кешегә бик кирәк. Файдага ярарлык дип тапкан фикерләрдән, бәлки, синең сорауларга җавап та табылыр? Анысын үзең карарсың.

Хат озынга китте. Нишлисең, Жан-Поль[1] әйтмешли, «...книги – это просто толстые письма друзьям!» Китаплар, хатлар – кардәшләр ич алар! Хуш булып тор.

Ихтирам белән Аяз.

### Ә. ЕНИКИГӘ[2]

1990, 9 ноябрь. Кич. Переделкино

Хөрмәтлебез Әмирхан ага!

«Татарстан яшьләре»ндәге Ф. Бәйрәмованың[3] «Башкорт суверенитеты» дип исемләнгән мәкаләсенә күзең төшми кал-

---

[1] Жан-Поль Шарль Эмар Сартр (1905–1980) – француз философы, язучы.

[2] А. Гыйләҗевнең Ә. Еникигә язган хаты язучының «Сайланма әсәрләр»енең 5 нче томына кертелгән (Казан: Татар. кит. нәшр, 2016, 441–443 б.).

[3] Фәүзия Әүхәди кызы Бәйрәмова (1950) – язучы, җәмәгать эшлеклесе, тарих фәннәре кандидаты (2006), Г. Исхакый исемендәге премия лауреаты (2001).

магандыр. «Лит. газета»дагы[1] монафикъ Жан Миндубаевның[2] «Татарстанцы-засранцы» дигән язмасы белән шушы мәкалә мине нык уйландырды. Бәйсезлек, суверенлык хакында сүз өскә чыгып, шул юнәлештә кайбер практик чаралар да күренә башлагач, мин «башкортлар ни кыйратыр икән? Башкортстанда яшәүче кан кардәшләребез татарларга ничегрәк карарлар икән?» дип уйлаштырып куйгалый идем. Асылда, Уфа белән мөнәсәбәтем берчакта да тыгыз булмады, хәзерендә борынгы бер-ике иптәшем белән хат алышудан узмый, әмма анда татарларны кысу дәвам иткәнен һәм аның ачыктан-ачык геноцид сәясәтенә әйләнгәнен ишеткәли идем. Татар матбугаты бу хакта сүзне пышылдап кына әйткәли иде, белгәнебез дә күп вакытта имеш-мимешләргә генә таяна иде. Мишәрләрне башкорт ясарга тырышып ятканда, татарларның протесты, ярсуы «Кызыл таң»[3] газетасында басылгач, материалларны Тәүфикъ Әйди[4] биргән иде шикелле. Айдар Хәлимнән[5] теге, «Дружба народов»та басылган мәкаләсе «Казан утлары»на килгәч, беренче булып Туфан Миңнуллин каршы чыкты. Ул үз мәнфәгатен күзәтте, татар-башкорт мөнәсәбәтләрендә ул берчакта да Казанны яклап бармады. Мин исә чираттагы ахмаклыгымны күрсәттем, Айдар Хәлимне бәяләүдә ялгыштым, егетнең җитди сүз әйтә алуына ышанмадым. Баксаң, без һаваланып, түш киереп йөргән арада, Айдар Хәлим дөнья сәясәтен дә, милли мәсьәләләрне дә глобаль масштабта аңлау дәрәҗәсенә ирешкән икән. Без күрмәгән, күрергә теләмәгән, күрмәмешкә салышкан бик

[1] «Литературная газета» – 1929 елдан басыла торган атналык иҗтимагый-сәяси газета.

[2] Жан Бари улы Миндубаев (1934) – язучы, публицист, ТАССР-ның атказанган мәдәният хезмәткәре.

[3] Башкортстан Республикасында 1944 елдан чыга торган иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни газета.

[4] Тәүфикъ Рамазан улы Әйделдинев (1941–2001) – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1991).

[5] Борис Нәҗметдин улы Хәлимов (Айдар Хәлим, 1942) – татар һәм башкорт язучысы, сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе. Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый (2009), Бөгелмә җәмәгатьчелегенең мәгариф буенча Һ. Атласи исемендәге (1995) әдәби премияләр лауреаты.

күп афәтләрне ул күргән, җыеп йомгак ясаган һәм дөньяга аваз салган иде: татарга башкорт экстремизмы яный! Үз вакытында без тревоганы ишетмәдек, күбесенчә ишетмәмешкә салыштык, язучылар корылтаенда Айдар Хәлимнең әрнүле хатын чыгып укыган Ркаилгә[1] борын җыердык, Туфан Ркаил адресына усал сүзләр әйтте... Мин башкорт-татар арасы бозык икәнне Ф. Хөснинең 50 еллыгында ишетеп калган идем. Уфадан кемдер килгән иде, без Казан ресторанының кече залында зыяфәттә[2] утырдык. Сүз иярә сүз чыгып, әллә башкорт җайсыз сүз әйттеме, әллә безнең кыдрач татарлардан берәрсе көйсезләндеме, күңелле генә барган мәҗлес аксап алды. Мин әлерәк кенә милләтләрнең канлы сугышлары арасыннан кайткан идем. Чекистлар, лагерьлардагы соңгы елларда урнашкан тоткыннар бердәмлеген чәрдәкләр өчен, милли суешларны оештырдылар, русларның — бандеровчыларга, бандеровчы украиннарның рус кешеләренә каршы сугышларына астан гына көч биреп, кыздырып, үзара дошманлыкны җылытып, коткы таратып йөрделәр. «Нигә сез шул хохолларга баш биреп торасыз?» — диделәр, русның яшьрәк егетләрен чакырып. Украинаның көнбатыш өлкәләреннән, әлерәк кенә урман ешлыкларыннан тотылып, төрмәгә утыртылган, каннары да суынып бетмәгән бандеровчыларга да шундыйрак сүзләр әйтелде: «Сез һаман шул москальләргә буйсынып яшисезме?» Русларга «кара»лар — чечен-ингушлар, үзбәк-казахлар һ.б. ялганды, бандеровчыларга берзаман литвалылар, «урман ияләре — яшелләр» кушылып китте... Күпме чеченны кырмадылар ул вакытта! Хак сугышларда исән калган бандеровчыларның күпмесе Казахстанның ташлы калкулыкларында эзсез-догасыз ятып калды!..

Башкорт-татар талашын ишеткәч, күз яшем белән җылаганым исемдә. Мин казанлылардан берәүне дә бу очракта аерып гаепләргә җыенмыйм, гаеп барыбызда да бар, хаталар уртак, без башкортның азынганын сабыр гына күзәтеп

[1] Ркаил Рафаил улы Зәйдуллин (1962) — язучы, публицист. Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге бүләге иясе (1990), Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2007), Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (2010).

[2] Зыяфәт — зыялы булып кылану.

тордык. Һәм менә көне килде, илдә ситуацияләр үзгәрә башлады, муенсыз милләтләр дә баш калкыта, тавышын ишеттерергә тырыша һәм башкортлар, русларга тәмам авышып, татарны мәсхәрә итәргә, татарның иңбашына басып, рус белән чут-чут үбешергә тотындылар. Без тамаша кылып яшәгәндә, көрәш уртасына көннән-көн ныграк кереп барган Фәүзия Бәйрәмова, ниһаять, экстремистларның, башкорт шовинистларының битлеген салдырды. Уфадан кайткан Ринат Мөхәммәдиев белән без кат-кат очрашкан идек инде, әмма ул, һәрвакыттагыча, башкортларның татарны мыскыллавы турында авыз ачып сүз әйтмәде.

Башкортлар соңгы һөҗүмгә күчкән, бу – шиксез. Ил болганганда, алар «бәйрәм» пирогыннан иң олы калҗаны эләктереп калырга ашыгалар, башкортның зурлыгын, көчен татарны изеп расламакчы булалар. Бу – көн кебек ачык. Менә мин ни уйладым, Әмирхан ага. Татарлар хакында ни уйлавыңны белдереп, искиткеч акыллы сүзләр әйттең. Татар-башкорт арасын синнән дә шәп, нигезле, әтрафлы белгән зат татарда юк. Хәтерең һәйбәт, шөкер, рухың үзеңдә, көчең җитәрлек – татарга да, башкортка да барып җитәрлек итеп, үткәзеп, бер мәкалә язып чыкмыйсыңмы? Бу – хәзер бик кирәк. Татарның көчен, ныклыгын, рухын күрсәтергә кирәк безгә. Башкортларга бирелгән сәдаканы – Мәҗит Гафурины каерып тартып алырга кирәк алардан. «Башкорт классигы» дип уйлауны кискен туктатырга вакыт. Башкорт әдәбиятына, мәдәниятенә көчен куйган актёрларны, әдипләрне, галимнәрне берәмтекләп, дәлилләп язып, татар тарихына беркетергә кирәк. Моны синнән башка кем эшли ала? Уйлама, миңа да, бүтәннәргә дә бу җәһәттән эш җитәрлек булачак, мин дә бу хәрәкәттә үз урынымны табармын. Менә бу хатым шуның беренче адымы түгелмени?..

Былтыр «Яра»[1] повестен бастырдым, быел йөз аклыгым булган «Балта кем кулында?»[2] басылды, төрле-төрле мәкаләләрдә, синең исемне калкан вә байрак итеп, дошманнарны кырам. Дәшмисең. Аңлыйм: Солженицыннар, Гросс-

---

[1] А. Гыйләҗевнең 1983–1988 елларда язылган повесте.

[2] А. Гыйләҗевнең 1988–1989 елларда язылган романы.

маннар[1], Дудинцевлар[2], Набоковлар[3] ташкын булып алга килгәндә, татарларга күз дә җитеп бетми торгандыр. Алай да... «Балта...»дан соң бер-бер фикер белдерерсеңме әллә, дип өметләнгән идем...

Мин монда, Мәскәү янында әле. Һава шәп, азык-төлек булмагач һава бозылулар беткән, бөтен шәһәр диетага күчкән, Миргазиян Юныс вегетарианец булып китәргә әзерләнә. Хәер, ул: «Без Әмирхан ага белән туктаусыз язышабыз»,– дип гаярләнә, аның хәлләрен үзең дә беләсеңдер...

Тик торган юк, мин дә кыймылдыйм. Уң ягымда Коръәннең русчасы, сулда – йөрәгем, уртада – күңелем. Каләм дигән компас кая алып барып чыгар.

«Скажи: «Пришла истина, и ложь не появится и не вернётся!» (Коръән, «Саба» сүрәсе, 48нче аять).

Тирән ихтирам белән, мәңге яратып, Аяз.

## Ә. ЕНИКИГӘ[4]

1991, 18 март. Көндез. Переделкино

Кадерлебез Әмирхан ага!

Хәтерендәдер, былтыр «Литературная Россия» газетасыннан Маргарита Ломунова Казанга килеп киткән иде. Безне аерым-аерым алып та сөйләште, Римзил Вәлиев[5] белән без аны Кырлайга да алып барып кайткан идек. Шул ханым газетаның быелгы 8 март санында «Ишкуатның дүрт угылы бар»

---

[1] Василий Семёнович Гроссман (Иосиф Соломонович Гроссман, 1905–1964) – рус совет язучысы, журналист.

[2] Владимир Дмитриевич Дудинцев (1918–1998) – рус совет язучысы.

[3] Владимир Владимирович Набоков (Владимир Сирин, 1899–1977) – рус һәм америка язучысы, тәрҗемәче, әдәбият белгече, энтомолог.

[4] А. Гыйләҗевнең Ә. Еникигә язган хаты язучының «Сайланма әсәрләр»енең 5 нче томына кертелгән (Казан: Татар. кит. нәшр, 2016, 464–468 б.).

[5] Римзил Салих улы Вәлиев (1949) – журналист, җәмәгать эшлеклесе. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1999). Ул елларда «Идел» журналының баш мөхәррире. – *Н. Гыйләҗева искәрмәсе*.

дигән мәкалә бастырды һәм шунда мине синең «преемнигың», ягъни шәкертең дип атады. Мәкалә болай җылы гына язылган, нәни генә хата да киткән, минем туган авылым Чукмарлыда мөселманнар яши, балачагым, үсмер чагым үткән Баграж тоташтан керәшен авылы иде. Ломунова, иренмичә, байтак китапларымны укыган һәм, моңарчы матбугат биргән бәяләргә караганда, дәрәҗәмне чак кына югарырак күтәреп язган. Илле яшем тулганда, мәрхүм Сарьян[1] олы бер сүз әйтеп калдырган иде, әлегәчә минем үземнең җан серләремне аңлап язган замандашымны күрмәдем. Сарьян әдәбиятның серен дә, эчке шәкелен дә, заман белән янәшә куеп, хәрәкәттә, дәвамлылыкта күрә ала иде. Бүтәнчә безнең заманда акылы, үз башы булган, үз башында үз фикерен төенли алган шәхес очрамады...

Юк, бүген зарланырга да, «аңламадылар!» дип лаф орырга да җыенмыйм. Сүзем әнә шул – Ломунова ханым әйткән «преемник»ка әйләнеп кайтыр... Шушы ай башында сиңа да 82 тулып үтте... Куанам: әле зиһенең ачык, рухың көчле, әйтер сүзең бетәрлек кенә түгел. Соңгы эндәшең бер башкортларга гына түгел, татарларга да акыл ирештергән көчле сүз булды. Һәм андый сүзне шундый югары кимәлдә бары тик син генә әйтә ала идең. Гомереңбуе туган төбәгеңә – Башкортстан туфрагына хөрмәт саклаган, иң көчле, егәрле фикерле әсәрең уртасына башкорт корткасы Ак әбине куйган азамат иргә уфалы дусларыңнан кырын караучылар да булгандыр, әмма заманалар үтәр, синең ул мәкаләң иң кыйммәтле тарихи документ булып сакланыр. Без, кызганычка каршы, әдипләребезнең эшчәнлеген бары тик бүгенге бизмәнгә салып кына үлчибез, бездә берсекөнгә түгел, иртәгәгә карый алу сәләте дә юк. Бу фәнни-документаль, фәлсәфи мәкаләң синең рухи батырлыгың булды, Әмирхан ага. Башкорт милләтчелеге котырган чак, ул гел алай булмас, тарихи гаделсезлекләр танылып, әз-мәз дөреслек урнашса, башкортлар да үз язмышларына бәрәкәтле тәэсир ясаган татар халкы белән арадашлыкка дөрес бәя бирерләр. Әле русның да чыннары, затлылары хөкемдарлар булып китәр, алар да милли мәсьәләләрдә хак юлдан барырга тырышырлар...

[1] Сарьян Салихҗан улы Хәсәнов (1930–1978).

Бу сүзем дә әле сүз уңаеннан гына!

Синең буын – сиксән яшьтәгеләр – чагыштырмача бәхетле буын. Сез – татарларны күргән, аралашкан, аларның барлыгына ышанган буын. Сез үзегез чәчкән орлыкларның бәрәкәтле татар туфрагына төшәчәгенә акыл белән дә, хис белән дә ышанган буын. Һәр язучының үзе ияртеп барган, ияртеп бара алган буыны була, халыкның аң дәрәҗәсен, хискә байлыгын, иманга мөнәсәбәтен замандаш язучылар билгеләсә, һәр буын үзенә хас, үзенә кирәк дип санаган әдипләрен алга этәрә. Булган, татар укучысы өчен Мөхәммәт Садри[1] – эшчеләр арасыннан күтәрелгән шагыйрь кирәк булган. Һәм ул туып мәйданга чыккан... Моны җырмоң аша раслау бик җиңел. «Без музыканы аранжировать итүчеләр генә, аны халык тудыра»,– ди Глинка[2]. Әдип тә үз чорының акылын җыючы түгелмени? Бәс, шулай икән, музыкага кайтыйк! Моңны халык арасыннан композитор дигән кеше җыя икән, мисалларга ерак барасы түгел. Билгеле бер чорда татарның музыкаль агымы тукталды. Хәзер Рөстәм Яхин[3] – иң соңгы могикан. Авырлык белән булса да, аның янәшәсенә, шактый түбәнгә Әнвәр Бакировны[4] да кертеп буладыр. Хәзерге заманның бу вазифаны башкаручыларына гына күз салыгыз... Миңа бөек Сәйдәшевнең бер аккорды җитә! Бер! Ул минем җанымны бөтереп ала да бөтен барлыгыма хуҗа була. Мин шатлыкта да, кайгыда да Сәйдәш белән янәшә була алам, ул мине адәм баласының бөтен халәтләрендә эзләп таба. Музыкаль сәләтем булмаса да, музыканы тирәнтен аңлыйм дип беләм үземне, җаныма якын асыл композиторларны дөнья классикасыннан да та-

[1] Мөхәммәт Садретдинов (1913–1999) – шагыйрь.

[2] Михаил Иванович Глинка (1804–1857) – рус композиторы.

[3] Рөстәм Мөхәммәтхаҗи улы Яхин (1921–1993) – композитор, пианист, педагог. РСФСРның (1981) һәм СССРның (1986) халык артисты, ТАССРның (1964) һәм РСФСРның (1970) атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1959).

[4] Әнвәр Закир улы Бакиров (1920–2001) – композитор. ТАССРның (1969) һәм РСФСРның (1981) атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1973), Татарстан Республикасының халык артисты (1993).

бып алдым мин: Вивальди[1], Григ, Бетховен... Бик нык яраткан җырчыларым да бар: И. Шакиров[2], Ә. Авзаловалар[3] миңа күпме көч өстәгәннәрен беләләрме икән?.. Хәзер үзешчән җырчыларда гына мин ярата торган татар моңы калды. Бүгенге татарлар исә, безнең белән янәшә яшәүчеләр, әнә шул балаган җырларын үз иттеләр. Алар шуңа табыналар... Китәр алдыннан хөрмәтлебез, ил агасы Миркасыйм хәзрәтләре Госманов[4] белән телефоннан сөйләшеп алдык. Былтыр аның җитди генә, бик кирәкле калын китабы чыккан иде. Миркасыйм хәзрәт тә офтанып торды: «Китап чыкты, беркемнең сүз әйткәне юк, газета-журналларның күзеннән читтә калды китабым!» – диде. 21–23 февральләрдә мин Зәй төбәгенең Бигеш авылында булдым. Кадерле әтиемнең вафатына – 15, сөекле әнием Мөгаттәрәнең үлеменә 10 ел тулган иде, туганнар җыйналышып, шуны билгеләп үттек... Мәктәпнең татар теле укытучысы, тәҗрибәле, күп еллар мәктәптән чыкмый яткан Әнвәрия ханым Хәйруллина[5] белән урамнан үтеп барабыз. «Авылда китап укучы калмады хәзер. Аңлы, белемле гаиләләр әллә кайчан авылны ташлап китте. Мәктәптә авыр укыган, дүрт-биш класс белән мәктәпне ташлаган адәмнәрнең балалары укый хәзер. Алма агачыннан ерак тәгәрәми, авылны балалар белән әнә шул чикләнгән аңлы, гарип-гораба, китап-дәфтәрне бар дип тә белмәгән ата-аналар тәэмин итә. Көчләп тә, үгетләп тә китапка тартып булмый аларны»,– диде Әнвәрия ханым... Сезнең буында композиторларның

---

[1] Антонио Лучо Вивальди (1678–1741) – Италия композиторы, скрипач, педагог, дирижёр.

[2] Илһам Гыйльметдин улы Шакиров (1935–2019) – татарның бөек җырчысы, ТАССРның (1969) һәм РСФСРның халык артисты, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1979), ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1970).

[3] Әлфия Афзал кызы Авзалова (1933–2017) – җырчы. ТАССРның халык артисты (1970), ТАССРның (1962) һәм РСФСРның (1983) атказанган артисты, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1992).

[4] Миркасыйм Габделәхәт улы Госманов (1934–2010) – тарихчы, археограф, язучы. ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1984).

[5] А. Гыйләҗевнең авылдашы.

көчле бер алае бар иде: Җ. Фәйзи[1], М. Мозаффаров[2], Заһид Хәбибуллиннар[3] замандаш татарларының күңеленә алтын ачкыч ярата алдылар лабаса! Рус Александр Ключарёв[4] татар-башкорт арасында гомер итеп, аларның дөньясына үтә алды!.. Юк, мин татар музыкасын билгеле бер калыпка сыйдырып, композиторларыбызны тар сукмакка кертеп, чыбыркылап бер юнәлешкә генә алып баруны хуп күрмим. Мәгәр без чорыбызның, тарихыбызның билгеле бер дәверен, бүгенгесен – татарның милли язмышы кыл өстендә торган мизгелне музыкабыз аша аңлатырга тырышсак... кемгә мөрәҗәгать итәрбез? Музыка да тарихи категория ләбаса! «Аракы эчтек тә «Җомга»[5] һәм «Шумел камыш»[6] көйләренә типтереп яшәдек»,– диярбезме?.. Әйе, татар тәрәзәләреннән күбесенчә «Хазбулат удалой»[7] җыры яңгырый шул. Рус-татар катыш туйда утырганыгыз бармы? Татарлар бер баштан җыр күтәреп карый, татарча җыр текстларын белүче юк... Менә рус ягы җырлап җибәрә, татарлар да чиный-чиный күтәреп ала. Без яшь чакта авылларда Тукай, Такташ шигырен белмәгән тере кеше юк иде!

[1] Җәүдәт Харис улы Фәйзуллин (1910–1973) – композитор, фольклорист. ТАССРның (1944) һәм РСФСРның (1957) атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның халык артисты (1964), ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1966).

[2] Мансур Әхмәт улы Мозаффаров (1902–1966) – композитор. ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1950), ТАССРның халык артисты (1964), Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1959).

[3] Заһид Вәли улы Хәбибуллин (1910–1983) – композитор. ТАССРның (1950) һәм РСФСРның (1981) атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты (1970), Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1968).

[4] Александр Сергеевич Ключарёв (1906–1972) – совет композиторы, дирижёр, пианист. ТАССРның халык артисты (1964), ТАССРның (1939) һәм РСФСРның (1969) атказанган сәнгать эшлеклесе.

[5] Татар халык җыры.

[6] Рус халык җыры.

[7] Рус халык җыры.

Авылларда йөргәндә, хәзер мин татар кешесеннән: «Берәр шигырь беләсеңме?» – дип сорарга шикләнәм...

Син үз буыныңны иңеңдә күтәреп килдең. Дөрес, каралу чоры, милли нигилизм, татарлыктан чиркану, татар исеменнән качу сине дә куа килде. Әмма синең әйтер сүзең билгеле бер милләткә – татарга төбәлгән иде. «Әдәби әсәрләр – халыкка адресланган озын хатлар ич алар» дигән акыллы кеше. Әле синең юлың якты, мәсләгең туры, «озын хатларыңны» салырга синең адресың да бар иде...

Милләте нинди язмыш кичерсә дә, әдип халкы белән бергә булырга тиеш. Кайсын Кулиевны[1] шул батырлыгы өчен яраттым – Мәскәүдә руслар канаты астына елышмый, сөргендәге милләте арасына бара, уртак язмышны сайлый... Ул чагында аңа сайлау артык катлаулы да булмаган, Кайсын уңны-сулны ап-ачык күргән...

Хәзер безгә нишләргә? Татар милли лидерларга ышанып яшәргә өйрәнгән халык түгел. Бер язган да идем шикелле: тарау халык без, таркау милләт. Бүген без, татар әдипләре, нинди кодрәтле сүз, нинди изге теләк, нинди якты иман белән халкыбыз алдына чыгып баса алабыз? Кирәкме без аңа бүген? Милләтне берләштерә торган нинди әфсен бар? Татарның җанына үтеп керерлек нинди тылсымлы үгет-нәсыйхәт бар икән? Калдымы икән алар дөньяда?..

Ломунова, «преемник» дип атап, мине шактый кыен хәлгә дә куйды. Моннан егерме еллар элек «Урталыкта» исемле, күбесенчә автобиографик әсәремдә «остазның куркак шәкерте булу»ның аянычлыгы хакында бер искәртеп киткән идем инде мин...

Ара-тирә мин сиңа «остаз» дип эндәшәм. Ләкин әле синең иҗат белән минем әсәрләр арасындагы «туганлыкны» ача алган кеше юк, аны мин тоям. Мин шулай уйлыйм. Моны бүтәннәр аермачык сизәдер дип расларга да теләмим, чөнки без – ике чор кешеләре. Безнең арада егерме еллык гомер ята. Татар тормышының иң караңгы чоры – милләтнең ашы-

[1] Кайсын Шуваевич Кулиев (1917–1985) – балкар совет шагыйре. КБАССРның халык шагыйре (1967), РСФСРның М. Горький исемендәге (1967), СССРның (1974) һәм Ленин исемендәге дәүләт премияләре лауреаты (1990).

га-ашыга һәлакәткә барган чоры. Буын белән әдәбиятның, сәнгатьнең ерагайган, аерылышкан чоры. Шуларга сызланып, минем нинди тәмуг газаплары кичерүемне берәр кеше күз алдына китерә ала микән?! Тирә-якта – шом, хаос, афәт. Шундый чакта халкың барырга тиешле маякны югалтканда ничек яшәргә мөмкин? Ничек иҗат итәргә? Кая карап табынырга? Ил матбугаты татарларга ябырылды, грузиннар патшасы Гамсахурдия[1] дә изә татарны, эстон депутаты Маде[2] да русларның кабахәтлеген «татар каны катнашкан» булу белән аңлата. Яңа гына чыга башлаган «День» газетасында Виктор Смирнов[3]: «Свишут стрелы, кровью брызнут зори. Под копытами кричит трава. Наших русских девушек позоря, огненно гогочет татарва»,– дип, шигырь яза. Монда Киевтан И. М. Росоховатский[4] дигән язучы бар, фантаст. Кичә референдумда «да» дип тавыш биреп кайтты. «Руска алмашка украин казаклары килә күрмәсен... Хәзер Украинада телләрдә Запорожская Сечь кына... Украина, Запорожская Сечьны күтәрер өчен, тарихка кайта һәм ике сүзнең берендә татарны каһәрли»,– диде...

Русның милли хисләре калка, монда, иҗат йортында, йодрык булып йомарланып килгән руслар яһүдләргә дошманлыкларын ачыктан-ачык бәреп әйтәләр, яһүдләргә төртеп-төртеп күрсәтәләр. Бөек милли лидерлары да пәйда булды: телләрдә – Шафаревич...[5] Димәк, алда безне тагын да авыррак милли язмыш көтә, инде бетеп барган халкыбызны упкын үзенә чакыра... Нишләргә? Ни кылырга?..

Монда ялгызмын, ялгызлыкта иманыңның кадерен беләсең, иманлы хөҗрәләрнең генә һәр почмагыннан сиңа яз-

---

[1] Звиад Константинович Гамсахурдия (1939–1993) – язучы, филология фәннәре докторы, Грузиянең Югары Советы рәисе (1990–1991) һәм беренче президенты (1991–1992).

[2] Тийт (Раймондович) Маде (1940) – эстон икътисадчысы.

[3] Виктор Петрович Смирнов (1942–2016) – рус шагыйре.

[4] Игорь Маркович Росоховатский (1929–2015) – украин язучысы, фантаст.

[5] Игорь Ростиславович Шафаревич (1923–2017) – рус математигы, физика-математика фәннәре докторы, 1958 елдан СССР Фәннәр академиясенең әгъза-мөхбире, Россия Фәннәр академиясе академигы (1991).

мыш елмаеп тора... Каушаган мәлләрдә ялгыз каласың икән, бу – куркыныч...

Кулыма Чыңгыз хан турында бик күп китаплар килеп керде, шуларны укып ятам. Бөек кеше булган икән ул, хәрби гений, тиңдәшсез дәүләт эшлеклесе. Кирәк чагында шәфкатьле дә булган, йомшак күңелле дә... Безнең татар бабайларның Чыңгыз тамырына тартылулары бер дә юкка булмаган икән. Алар Чыңгызның тарихтагы урынын дөрес аңлаганнар...

Ярар, сүзләрем күп иде, туктыйм. Сиңа, кадерлебез Әмирхан, көч-куәт, җан тынычлыгы вә тынычсызлыгы, сөенечле яз теләп калам.

Тирән ихтирам белән, яратып, Аяз.

ЯШЬ ЯЗУЧЫГА

1991, 27 июль. Иртәнчәк. Казан

Рәшит иптәш![1]

4 мартта язган үтенеч-хатыгыз, күңелне тырнап, эш кәгазьләрем арасында күчеп йөри. Мәскәүдән кайттым да мең төрле мәшәкать арасына чумдым: алдагы елларда чыгарга тиешле дүрттомлыкның ике томын шушы айның унынчы числосында гына производствога төшереп җибәрдек. Эш үзе вакытны ул кадәр күп алмый, «эшлисе бар, эш күтә!» дип борчылып йөреп гомер үтә, вакытны исә төрле вак-төяк, агымдагы эшләр, утырышлар, гел кирәкмәгән шөгыльләр умыра... Бик күп чүп-чар укырга туры килә. Хәзер элеккеге егәр, тизлек юк, дөньяны аңлау өчен күпме көч сарыф ителгәнен санасаң!..

14 сорау юллагансыз. Әгәр аларның һәммәсенә үз эш тәҗрибәмнән, чиккән газапларымнан, тау-тау язган кәгазьләремнән чыгып тулы җавап бирергә тырышсам... үзе бер-ике диссертация булачак! Шаяру түгел, чөнки һәр әдип иҗаты – билгеле бер чорның әдәби агымын билгеләүче көч ул; минем яшәеш, иҗат омтылышлары үз чордашларым белән тыгыз бәйләнгән.

Безнең әдәбият белемендә әдәбиятны тоташ бер агым итеп күз алдына китерә алырлык кеше әлегә юк, әдәбият

[1] Рәшит иптәш – яшь язучы.

ташкын булып ага, безнең бичара белгечләр яр буеннан, камыш арасыннан, аякларын чылатырга куркып, плащ якаларын күтәреп, ышыкланып, чәнчә бармакларын сак кына манчып алалар да агымның көче, аның кай урыннарда ярсып-ашкынып, кай тарафта тынып-туктап торуын бәян итәргә азапланалар. Агымның үзәгенә («стремнина» ди аны рус) әдипләр белән бергә үтә алган, юлдагы кыяларны ватып узган талант эзләрен күзәтергә көче җиткән әдәбият белгечләре бездә юк. Гомумән, әдәбият фәне югары дәрәҗәгә ирешкәндә, тормыш фәненә әйләнә, Энгельсның[1] Бальзак[2] романнарына биргән бәясен хәтерлисездер. Мин соңгы утыз биш елда тоташтан иҗат агымына кушылып яшәдем, бардыр аның ялгыш якка кереп киткән ермаклары, бардыр аның туктап, бүтәннәргә кыенлык китергән бормалары, мәгәр бер нәрсә ачык: мин берчакта да кире борылмадым, гомуми агымга көч бирергә, егәр өстәргә тырыштым. Агым юлында очраган бусагаларны гел-гел урап үтмәдем, байтагысын тибеп аудардым, хак юлдан тайпылмадым...

Булды, бил сынган чаклар булды, муен үзеннән-үзе борылды, башны хуҗа итә алмады. Нишлисең, яман чорда яшәдек, ерак бабайларны бөккән яман көчләр, тамырлардан тамырларга күчеп, безгә дә килеп иреште. Әдәбият ул – күп тамырлы милләт агачы. Чын тамырларга паразитлар, халтурачылар, ябышкак саламторханнар да иярә, алар чын тамырларны азыкландырырга тиешле милли туфракны көне-төне имәләр, бер ваемсыз рәхәт чигеп яшиләр. Әдәбият берчакта да янәшә мыжгучы кортлардан, паразитлардан аерыла алмый... һәм шул паразитларны «чын тамыр!» дип көнгә чыгаручы кара йөзләр дә әдәбиятта була.

Яңа, тере мисал. Габделхәй Сабитовның[3] алтмыш еллыгы уңаеннан тәнкыйтьче Мансур Вәлиевнең «Безнең Габделхәй абый!» дигән, дәлилсез мактаулардан торучы мәкаләсе дөнья күрде. [...] Яфрак астында ятты-ятты да Ф. Бәйрәмовага, Татар иҗтимагый хәрәкәтенә лач итеп төкереп газетада

[1] Фридрих Энгельс (1820–1895) – немец философы, марксизмга нигез салучыларның берсе, Карл Маркснның дусты.

[2] Оноре де Бальзак (1799–1850) – язучы, романнар остасы.

[3] Габделхәй Вәли улы Сабитов (1931–1995) – язучы.

бер селтәнеп алды. «Безнең» ди М. Вәлиев. Кемнең? Кем исеменнән сөйли М. Вәлиев-тәнкыйтьче? Татар халкы исеменнән сөйләргә кем аңа хокук биргән? «Безнең» ди икән, димәк, ул тар бер төркемнең вәкиле булып чыга?! Әйе, андыйлар берчакта да ялгыз булмый, аларга да укмашып, үз агымнарын тудырып, үзләренчә эш күрсәткән булып яшәргә кирәк.

Димәк, әдипкә бәя бирергә телисез икән, уңны-сулны анык, төгәл билгеләргә, иҗатының чишмәсен, су башын эзләп табып, аның агымының юнәлешен, агымының көчен, кайсы кырны сугаруын, китергән файдасын, җыелган уңышын күз белән күреп, акыл белән үлчәп-бәяләп сөйләшергә кирәк.

Язучы өчен иң мөһиме — хәтер. Хәтер ул — үзең үткән бормалы, авыр юллар, табышлар вә югалтулар, мәхәббәт газаплары, астыртын һәм өстертен дошманнар белән көрәш... Чын әдип һәрнәрсәнең бары тик чынын татырга тиеш. Мәхәббәттә ул мәҗнүн, көрәшләрдә ул алып батыр, сагышларда нык, хәсрәттә чыдам, максатына ирешәм дигәндә, үзсүзле, тәвәккәл, тугры, хөкемдә гадел һәм башкалар. [...] Чыпчык җилен давыл дип, черки безләвен дошман явы итеп кабул иткән бик күп шагыйрьләр тәкәрлек түмгәген Каф тавы дип саныйлар. Әдип иң беренче нәүбәттә үз-үзенә аяусыз булырга тиеш! Әдәбият ул — эш, тынгысыз, авыр, өзелмәс хезмәт. Мин иртәнге дүрттә-биштә уянмаган әдипне чындыр дип санамыйм. Янәшәңдә дөнья, җир уянганда, син, йоклап ятып, хәрәкәттән төшеп каласың, язучы үз табигате белән табигатьне яраштырырга, ике яктан да сулышны тигезләргә тиеш. Тормыш аңа хатирә бүләк итә, хатирә — аның юл сакчысы. Әдип гомере буе үз тормышын, үз кичергәннәрен, үз тәҗрибәсен яза. Мин үзем тоймаганны, үзем күрмәгәнне, үзем йөрмәгәнне берчакта да язмадым. Әдип һәр адымында, һәр сулышында әдип ул, аның җете күз карашыннан бернәрсә дә читтә кала алмый, аның зиһене, акылы, күз-колагы берчакта да ял итми. Бер гадәтләнгәч, табигатеңне күнектергәч, һәрнәрсәгә бары тик әдип күзлеге белән генә карыйсың, бигрәк тә олыгайгач, акыл һәм зиһен ял табалмыйча газаплана, син дөньяның дүрт ягындагы чәбәләнешләреннән үзеңә акыл

сөзәсең, үз иманыңның дөреслеген тикшерәсең, дөнья кешеләренең газабын, ялгышларын — һәммәсен үзеңә кабул итеп аласың. Кеше күңеле, хатирәләр диңгезенең чиге-ярлары юк, ул төпсез, аңа ай-кояш та, мәхәббәт ташкыннары да, хәсрәт шарламалары да — һәммәсе дә сыя. Иске күзәнәкләр үлә тора, Хода кодрәте белән күзәнәкләр яңара, олыгайгач, кеше ел саен бер тапкыр яңадан туа. Бер нәрсә какшаусыз кала: иман! Әгәр әдип үз күңелендә какшамас иман туганын тойса, бу — бәхетле әдип. Һәм аның иманы юл яктыртып алга, һәнүз хәрәкәткә чакырып тора. Андый әдипләрнең әйтер сүзе кимеми, берчакта да бетми. Минем һәрчакта да унъеллык планнарым әзер булып торды. Мин каләм очы кимереп илһам килгәнне көтеп, урын алыштырганда, һава үзгәләп яшәмәдем, әйтергә омтылган сүзем шулкадәр көчле, тере идем, минем эшсез утырган көннәрем юк, язмыйча калган көннәремдә зиһен һаман хатирә коеларын казый, актара, рудаларны эшкәртә, көненә бер кадерле сүз таба алсаң да, чиксез бәхетле буласың. Әсәр күпчелек очракларда ми тартмасының чиксез күзәнәкләр даирәсендә озак өлгерә.

Әйтик, берзаман «Азат хатын» журналында мин «Җомга көн, кич белән...»[1] хикәясен язам дип белдергән идем. Әсәр ун-унбиш елдан соң гына өлгерде. Мин моңа сөенәм, чөнки әсәр язу уе белән әдип үзе үсә, иң мөһиме — әсәр генә түгел, автор үзе дә өлгерергә тиеш. Менә нәрсә кыйммәт! «Балта кем кулында?» исемле төп әсәрләремнең берсен мин җитмешенче еллар башында язарга ниятләгән идем. Ә ул егерме ел үткәч кенә язылды. Чиксез бәхетлемен: җитмешенче еллар башында мин бер төсле әдип булсам, туксанынчы елларга якынлашканда, мин бүтән кеше инде. Шул кеше дә, ул да түгел. Әдип кан алышынуларын кичермәсә, аның каны бозык шәрабка әйләнә. Күпме бездә шул иске каннарын саклап гомер кичүче талантсызлар! Менә Барлас Камалов. Хәзер ул үзгәрергә маташа, үзгәрә алмый. Чөнки туганнан бирле, алтмыш ел яшәеш дәверендә, ул канын яңартмады, дөньяны аңларга көч түкмәде, власть әһелләре ни дисәләр, шуны хуплады, шикләнмәде, икеләнмәде. Шикләнү, икеләнүләр әдипнең үзендә булган очракларда да, әсәрләренә күчәргә

[1] А. Гыйләҗевнең 1972–1979 елларда язылган повесте.

тиеш түгел! Әз генә йомшаклык, икеләнү ычкындырганда да, соңра бу зур үкенечләргә китерәчәк.

Без татарлар – үтә надан халык. Безнең милли көчне билгеләүче, милләт байрагын алга илтүче зыялыларыбыз юк. Бөек – галимебез Әбрар Кәримуллин[1] моны әллә кайчан билгеләде инде, ул: «Эшләмичә бай булырга, укымыйча гына муллалыкны алырга әзер халык ул татар»,– дигән иде. Кичәге «Соц. Татарстан» – газетасында мәшһүр әдибебез Мөхәммәт Мәһдиевнең гыйбрәтле, хикмәтле мәкаләсе басылды. Әйе, әрнеп, борчылып кабатлыйм: без – надан халык.

Бездә интеллектуаль әдәбият юк. Була да алмый. Безнең укучылар арыш саламына әз-мәз арыш оны туглап биргән башакны рәхәтләнеп күшиләр. Арзан зәвыклы әдәбият алгы планда йөри. Китапханәләр үткәргән тикшеренүләрдә иң арзанлы әсәрләр күп очракта алгы планга чыга. Г. Әпсәләмов ун, егерме еллар дәвамында иң күп укылган, иң күп басылган автор булды. Бүген ул – ноль! [...] Без әле бик озакка кадәр (әгәр татар милләте яшәсә, әз-мәз тернәкләнә алса!) аның чир кәсафәтен сизеп киләчәкбез, тоячакбыз. Надан укучыга акыллы әдипләр кирәкми. Безнең язучыларыбыз да шыр надан. Мин берзаман Туфан Миңнуллинга Эрнест Хемингуэйның «По ком звонит колокол»[2] дигән гүзәл романын биргән идем. «Аңламыйм» дип, кире кайтарды. Шәүкәт Галигә ничә мәртәбә Меша Селимовичның[3] «Дервиш и смерть»[4] исемле тиңсез талантлы әсәрен тәкъдим иттем. «Ни таптың син аннан?» дип гаҗәпләнеп, китабымны кайтарды. Меша Селимовичны укымыйча торып, Коръәнне, Көнчыгышның дини философларын аңлап булмый. Ә бүген Коръәнне, Библия-

---

[1] Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин (1925–2000) – татар галиме, милли хәрәкәт әгъзасы, китап белгече, библиограф, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы. ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1990), Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе (1991), Кол Гали исемендәге халыкара бүләк лауреаты (1995).

[2] Э. Хемингуэйның романы (1940).

[3] Меша Селимович (1910–1982) – XX гасыр сербохорват әдәбиятының танылган язучысы.

[4] Меша Селимович романы (1966).

не укымаган әдип – әдип була аламы? Даниил Андреевның[1] яңарак дөнья күргән «Роза Мира» китабын[2] әйтмим дә инде. (Үзем дә ул китапка кереп кенә барам! Балаларым да укый. Як-ягыма каранам: надан шул без, әзерлексез татарлар!)

Әсәрләргә кешеләр тормыштан, газеталардан, ләкин әдипнең үз аңы, үз хәтере, үз иманы аша үтеп, сыгып, иләнеп киләләр. Авторның хәтер-компьютеры шулай тиз эшли ки, һәр ишетелгән яңа сүз, яңа хәбәр, тормышның моңарчы аңа мәгълүм булмаган төсмере шунда ук үз урынын ала. Мин үзем алдагы унъеллык планга кертеп куйган әсәрләремне уйда һәрчак дәвам итәм, яңа ым, ят ишарә, яңача ракурс табылганда, аны шунда ук алдагы әсәрдә урынын эзләп табып беркетәм. Сирәк-мирәк кенә куен дәфтәрләремә дә терким. Куен дәфтәрләрем сыек. Минем тормышым – дус-ишләргә, туганнарга язган хатларымда. Мин елына 200–300 хат язам.

Эшнең бисмилласы, башы авыр. Беренче җөмлә үзенең ритмы, музыкаль агышы белән әсәрнең тукымасын, буй җепләрне ияртә, син аркау җепләрен – вакыйгаларны, кешеләрнең гамәлләрен иплэп-сипләп кенә барасың. «Өч аршын җир»[23] повестеның керешен мин утыз тапкыр язып карадым...

Әдип, юлын эзләгәндә, әдәбияттан үзенә фикердәшләр, рухи кардәшләр табарга тиеш дип саныйм. Үзеңнең сукмагыңны алар салган нык, сыналган юллар белән чагыштырып карыйсың, ә бу һәрчак сине чынлыкка өнди, турылыкка хыянәт итмәскә чакыра. Мин үземә рухи кардәшләрне төрле әдәбиятлардан төрле вакытларда эзләп таптым. Юрий Казаков[3], Эрих Мария Ремарк, Экзюпери, Хемингуэй[4], Бернард Шоу, Ибсен[5], Фатих Әмирхан, Әмирхан Еники... Менә алар минем сүзсез юлдашларым. Әмирхан Еники берзаман: «Син – бөтенләй бүтәнчә уй йөртүче, үзеңнең стилең бар

[1] Даниил Леонидович Андреев (1906–1959) – рус язучысы.

[2] Д. Андреевның китабы (1958).

[3] Юрий Павлович Казаков (1927–1982) – рус совет язучысы.

[4] Эрнест Миллер Хемингуэй (1899–1961) – америка язучысы, журналист, әдәбият өлкәсендә Нобель премиясе лауреаты (1954).

[5] Генрик (Хенрик) Юхан Ибсен (1828–1906) – норвег драматургы, шагыйрь һәм публицист.

язучы... Син ничек мине остазың итә аласың?» – дип сорады. Әйе, югарыда саналган бөек әдипләрнең һәммәсенең үз иҗат йөзе, үз темасы, үз эш алымнары бар, ләкин аларны ныклы бер нәрсә берләштерә: ул гаделлек, гади кешегә хас ихлас һәм эчкерсез мәхәббәт, гуманизм. Әмирхан ага белән без татар милләтенә мәхәббәтебезне төрле юллар аша, төрле кешеләр күңеле аша үткәрсәк тә, ул – ихлас мәхәббәт. Без – милли язучылар. Үз арабызга мин арабыздан иртә киткән Хәсән Сарьянны, Фаил Шәфигуллинны[1], Мөхәммәт Мәһдиевне генә кертер идем...

Әгәр сез, Рәшит иптәш, шәһәрдә яшәсәгез, бу хат язылмаган булыр иде. Анда өр-яңа фикерләрем юк, мондагы уйсүзләр матбугатта күренгән мәкаләләрдә сибелеп ята, сезгә бераз укмаштырып җибәрәм. Бәлки, соңга да калганмындыр, анысы өчен кичерерсез.

Уңышлар теләп, сәлам белән, Аяз.

[1] Фаил Хафиз улы Шәфигуллин (1939–1982) – татар язучысы.

# Әңгәмәләр

## Бүгенге әдәбиятта замандаш образы

*(Фәрваз Миңнуллин радиоәңгәмәсе, 17 июль, 1975, Казан)*

Мин үзем саф практик булсам да, әсәрләр өстендә эшли-эшли, фикердәш язучылар, белгечләр белән аралаша-аралаша, әдәбиятның кайбер эчке мәсьәләләре турында да уйланырга, фикер йөртергә туры килә. Игълан ителгән темага турыдан-туры кереп китәрдән элек, кереш рәвешендә, бер гомуми мәсьәләгә чак кына тукталып узасым килә.

Без барыбыз да, шул җөмләдән тәнкыйтьчеләр дә, аны-моны уйлап та тормастан, «әдәбият үсә дә үсә» дип расларга яратабыз. Дөрес, әдәбият һәм сәнгать – тере организм. Заман, вакыт, тарихи вакыйгалар, халык һәм аерым шәхесләр язмышы аны һәрвакыт тукландырып тора. Аның күзәнәкләре туктаусыз яңарыш кичерә. Әйе, бу күзәнәкләр юктан гына барлыкка килмиләр, ә дәвамлы, туктаусыз процессның бөҗралары булып торалар. Үсешне чылбыр рәвешендә күз алдына китерсәк, хәзерге заман язучылары иҗатын әнә шул бөҗраларның берсе итеп карый алабыз. Димәк, бүгенге әдәбиятның элекке традицияләргә бәйле булуы да, киләчәк буын бөҗраларын тудыра алырлык көчкә ия булуы да шарт икән.

Бу процессны без гади генә итеп «әдәбият үсә» дип сөйлибез. Үсә, дибез дә, сүзебезне дәлилләр өчен мисаллар да китерәбез. Аның тематикасы, сферасы киңәя, дибез. Әдәбиятчыларыбыз кеше күңеленә тирәнрәк үтеп керә, дибез. Бүгенге заман иҗатчыларына психологик дөреслек хас, дибез. Болар барысы да дөрес. Ләкин үсү – Тукайларны, Фатих Әмирханнарны, Мәхмүт Галәү, Галимҗан Ибраһимовларны үтеп китү дигән сүзме?.. Әллә әнә шул әдәбият корифейлары

тудырган югарылык дәрәҗәсендә иҗат итәргә омтылумы? Әлбәттә шулай. Әдәбият үсә, дибез икән, без аның бүгенге торышын, стиль формаларын, образлар системасын Тукай–Әмирханнар иҗаты белән чагыштырып карап сөйләшәбез. Безнең кулыбызда мәңге үзгәрмәс, мәңге тутыкмас эталон бар – ул безнең гүзәл әдәбиятыбызның тарихы, безнең онытылмас классикларыбыз.

Әдәбиятның икенче бер кызыклы ягы – һәр язучы үзе белгән, үзе кичергән, үзе яшәгән конкрет чор өчен җавап та бирә. Үткәннәр турында язамы ул, хәзерге көн геройларына мөрәҗәгать итәме, кыю рәвештә киләчәккә күз салып фантастик әсәрләр тудырамы – болар барысы да заман ихтыяҗларыннан чыгып эшләнәләр. Язучы укучыны үз артыннан ияртеп барган шикелле үк, үз чоры кешеләре, үз укучылары артыннан да ияреп бара.

Әгәр ул үз чорын, үз чорының вакыйгаларын, кешеләрен, тарихи процессны дөрес аңлап, намус кушканга хыянәт итмичә иҗат итсә, аның әдәбиятта безгә мәгълүм булган, без байрак итеп күтәргән югарылыкка ирешү ихтималы бар. Әдәбият бер чакта да ялганны, ялагайлыкны, чорга хыянәт итүне кичермәде һәм кичерми дә.

2. Без бая язучының үз чоры өчен җаваплы булуы турында сөйләгән идек. Мөгаен, һәр язучының үз чорының продукты булуы турында бәхәс купмастыр дип уйлыйм. Мәсьәләнең икенче бер мөһим ягы да бар. Хәзер сүзне шуңа юнәлтәсе килә.

Образга, әсәр героена бәһа куйганда нинди критерийлардан чыгып эш итәргә кирәк?.. Минем өчен әсәр героеның киләчәк язмышы булуы шарт. Әгәр ул чыннан да хаклы рәвештә бүгенге көннең асыл сыйфатларын, бөтен бизәкләрен үзендә туплаган икән, бүгенге көннән киләчәк буыннарга тулы вәкаләтле илче булып бара ала икән – бу образ әдәбиятта онытылмый инде. Нигездә кешелеккә бер үк сыйфатлар хас – яхшылыкка омтылу, гадилеккә омтылу, тапкырлыкны мактау, дуслыкка дан җырлау борынгы әкиятләрдән үк килә бит. Ләкин бу сыйфатлар һәр чорда үзләренең социаль төсмерләрен алганнар. Моннан шундый бер аңлатма чыгарып була, әгәр образ чын кеше булсын дисәң – ул образ язмышы

артында конкрет бер халык, үзенең милли сыйфатлары белән ачыкланган халык торырга тиеш. Соңгы вакытларда рус әдәбиятында бара торган кызыклы бер процесска күз салыйк. Җиңел куллы бер иш язучылар төньяк халыклары тормышы турында бик күп яза башладылар. Чукчалар, ненецлар турында соңгы елларда том-том әсәрләр язылды. Милли экзотика, йолалар, кием-салымдагы, гореф-гадәтләрдәге үзгәлекләр укучыны да, язучыны да тарталар. Мин моның белән әдәбиятларны милли тарлыкка чакырырга теләмим, әмма әсәр конкрет бер халыкныкы булып кына туа ала. Соңгы елларда татар әдәбиятында аерата күренекле булган берничә әсәргә тукталыйк. Әйтик, Гариф Ахуновның «Хәзинә»[1] романының уңышы нәрсәдә?! Әсәрнең төп уңышы – аның төп геройларының халык язмышына, татар халкының бүгенгесенә тыгыз бәйләнешле булуында. Әсәрдәге кешеләр дә, вакыйгалар да тарихи дөреслек кушканча үсәләр, үзгәрәләр. «Чикләвек төше»[2] повестенең төп герое Халикъ Саматов образында да ил язмышы, халык язмышы тулаем чагыла. Милли җирлеге булган, халык тормышына тугрылыклы булган әсәрләрдән тагын икесен: күренекле язучыбыз Әмирхан ага Еникинең «Җиз кыңгырау»[3] хикәясен һәм замандашым, талантлы каләм иясе Мөхәммәт Мәһдиевнең «Әйдә барыйк, кызлар карыйк»[4] исемле әсәрен атыйсым килә. Бу ике әсәргә халык характерын, аның изге йөрәкле, музыкаль кешеләрен ачу хас. Мәһдиев үзе «Фольклорчы язмалары» гына дип атаса да, никадәрле шигърият бар ул хикәядә! Анда исемнәре саналган кешеләр – чын-чыннан халык вәкилләре, үз чорларының төсмерләрен күңелләрендә туплаган якты кешеләр. Без бу әсәрләрдән тарихны да, этнографияне дә, фольклорны да, гүзәл йолаларыбызны да – барын да белә алабыз. «Җиз кыңгырау» хикәясенең шушы арада гына болгар теленә тәрҗемә ителеп басылып чыгуы ишетелде. Хаклы рәвештә эшләнгән тәрҗемә!

[1] Г. Ахуновның 1963 елда язылган романы.

[2] Г. Ахуновның 1973 елда язылган повесте.

[3] Ә. Еникинең1966 елда язылган хикәясе.

[4] М. Мәһдиевнең «Фольклорчы язмалары»ның 1973 елда «Казан утлары»нда басылган бүлеге (№ 10, 164–175 б.).

Бу уңайдан Мәхмүт Галәүнең «Мөһаҗирләр»ен, «Болганчык еллар»ын[1], Гомәр ага Бәшировның «Намус» романын[2], Кави Нәҗминең «Язгы җилләр»ен[3] дә телгә алып китәсем килә. Болардан безнең күңелләргә күчкән образлар нәкъ менә тарихи җирлектә, бары тик татар халкы җирлегендә генә туа алганнар. Шул уңайдан Шамил Бикчуринның «Каты токым»[4] романын да искә төшереп китик. Әгәр аның Мут Гәрәйләре булмаса, әсәр шул тиклем кызыксыну уята алыр идеме?!

4. Ни өчен теге яки бу автор күңелләрдә калырлык образлар иҗат итә ала да, аның китабы озак елларга кадәр безне сокландыра? Яки, киресенчә, авторның бик заманча яңгыраган кебек әсәре бик тиз халык арасыннан төшеп кала, югала, онытыла. Бу – тулаем авторның үзенә, аның талантына гына түгел, талант хезмәт итә торган мәсләгенә, тоткан юлына тугры булуына бәйләнгән. Кайчандыр бер әңгәмәдә, мин әсәрнең төп герое – аның авторы, тудыручы язучы дигән идем. Еллар үтә торса да, бу иманым какшамады, киресенчә, аның шулай икәнлегенә ышанычым гына арта бара. Үз мәсләкләре булмаган, халык-заман ихтыяҗларын тулы аңламаган, тоткан юлларында нык тормаган кешеләр, әдәбиятта очраклы булуларын сизгән кебек, берәм-берәм төшеп калдылар. Үз юлы булу, ул юлның ил, халык, тугрылык өчен көрәш юлы белән тәңгәл килүе – язучының активлыгын билгели. Үзе никадәрле актив булса, көрәш сызыгында торып иҗат итәргә курыкмаса, язучы каләме астыннан актив, көрәшче геройлар туа. Язучының тоткан юлы әсәрләрендә ап-ачык чагылыш табарга тиеш. Әйтик, соңгы елларда әдәбиятка килгән яшь язучы Әхәт Гаффаровны алыйк. Әхәт нибарысы бер генә китап, юка гына «Әҗәт»[5] исемле беренче китабын чыгарып өлгерде. Ләкин аның шушы китабы да калын-калын томнар чыгарып ятучы кайбер язучыларның иҗатларыннан кадерлерәк. Ни өчен? Чөнки әдәбиятыбызда яңа кеше туды, яңа автор килде, чын язучы яралды. Бу инде әдәбиятта очраклы кеше түгел. Чөнки ул заманның үзеннән,

[1] Мәхмүт Галәүнең 1930, 1934 елларда язылган тарихи дилогиясе.

[2] Гомәр Бәшировның 1943 елда язылган романы.

[3] Кави Нәҗминең 1949 елда язылган романы.

[4] Шамил Бикчуринның 1972 елда язылган романы.

[5] Ә. Гаффарның 1975 елда чыккан китабы.

кайнап торган тормышыбызның үзеннән килә. Салкын күзәтүче яки эчпошыргыч беркетмәче булып түгел – актив көрәшче булып килә. Аның көрәшче икәнлеген шушы нәни генә китабы да ачык раслый. Әхәт үзе язган темаларны йөрәге, күңеле аша уздыра ала, үзенең тормышка актив мөнәсәбәтен ышанып һәм ышандырып әсәр геройларына тапшыра. Мәсәлән, «Әҗәт» хикәясендәге Мәрьям әби образын алыйк. Гомере буе илгә, халыкка тугры хезмәт иткән, намуслы эшсөяр бу кеше үзенең дөньядагы зур бурычын аңлавы белән безне таң калдыра.

Әхәт Гаффаровның теле, язу стиле, ритмы, эчке яңгырашлары – һәммәсе дә заманча, үзенчәлекле. Бер үк вакытта аның әсәрләре – нәкъ без алда әйтеп киткән бөҗраларның берсе. Анда телебезнең сыгылмалы яңгырашы да бар, анда күңелне тетрәтерлек вакыйгалар да бар, алар барысы да – безнең халыкныкы, безнеке. Ул үзенең кешелекле, нечкә күңелле, яшәешнең бәйрәм генә түгел, бәлки зур бурыч икәнлеген дә аңлап эш итүче персонажлары-образлары аша безне яктылыкка өнди, киләчәккә булган ышанычыбызны ныгыта. Бу сыйфатлар барысы да язучының үзеннән, аның эчке дөньясыннан, аның иманыннан, яшәүдәге активлыгыннан килә. Салкын кан белән, суык йөрәк һәм бары тик расчет белән генә иҗат ителгән образлар караңгы базда үскән бәрәңге сабаклары төсле төссез булалар һәм бервакытта да җимеш бирмиләр.

## Тормыш чынбарлыгын исбатлап

*(Зиннур Хөснияр[1] радиоәңгәмәсе, 1988)[2]*

Хөрмәтле радиотыңлаучылар, сезне «Тормыш чынбарлыгын исбатлап» дигән тапшыру тыңларга чакырабыз. Ул РСФСР һәм

[1] Зиннур Зыятдин улы Хөснетдинов (Зиннур Хөснияр, 1961) – язучы, «Сәхнә» журналының баш мөхәррире, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2001), Ш. Маннур, Ф. Хөсни (2001), Г. Исхакый (2008) исемендәге әдәби, М. Сәлимҗанов исемендәге театр (2019), М. Җәлил исемендәге Республика яшьләр (2009) премияләре лауреаты. Зиннур Хөснияр 1987–1989 елларда «Татарстан» радиосында әдәби-драматик тапшырулар редакциясе мөхәррире булып эшли.

[2] Тормыш чынбарлыгын исбатлап / А. Гыйләҗевнең З. Хөснияр белән радиоинтервью. 1988 ел. 8 б.

ТАССР дәүләт премияләре лауреаты, язучы Аяз Гыйләҗевкә 60 яшь тулуга багышлана. Әлеге тапшыру уңаеннан без студиягә әдипнең үзен чакырдык, һәм хәбәрчебез Зиннур Хөснетдинов язучыга берничә сорау белән мөрәҗәгать итте.

— *Аяз Гыйләҗев – татар совет әдәбиятының әйдәп баручы, әйтергә кирәк, иң төп йөген тартып барган күренекле язучыларның берсе. Мин әлеге тапшыруны әзерләгәндә шул хакта уйландым: теге яки бу мәсьәләләргә карата әдипкә сорау бирү үзен аклар микән? Чөнки язучының барлык фикере, уй-гамәле аның әсәрләренә салына бит. Сорауларың булса, әсәрләргә мөрәҗәгать ит. Ләкин бүгенге кызыклы заманда җавап таләп иткән сораулар бихисап шул. Аларга җавапны нәкъ менә танылган язучыдан, фикер иясеннән ишетәсе килә. Билгеле инде, беренче соравым язучының әсәрләренә бәйләнешле рәвештә булырга тиештер. Аяз Мирсәетович, сезнең иҗат турында сүз чыкканда, гадәттә, «халыкчанлык» сүзен еш кулланалар. Бу – бик тә тирән мәгънәле, зур сүз. Әлеге төшенчәгә карата сезнең фикерләрне дә ишетәсе килә.*

— Халыкчанлык – искиткеч зур эчтәлекне сыйдыра торган эш, дип кабул итәм мин. Һәм, гомумән, минем әсәрләргә кагылышлы рәвештә «халыкчанлык» дисәк, мин бу сүздән сагаеп калам. Чөнки халык үзе – тораташ каткан, үзгәрешсез бер масса түгел ич. XX гасырда халык бер төрле булган, революциядән соң ул бик зур үзгәрешләр кичергән. Соңгы унъеллыкларда ул гаҗәеп дәрәҗәдә төрле-төрле яшәү шартларын татыды. Һәм шуның өчен, теге яки бу әсәр халыкчан дип, мөһер сугып куеп була микән? Бу эш хаклы булыр микән? Үзегезгә мәгълүм: буыннар үзгәргән саен, әдәбиятка, кайсыдыр вакытта халык арасында киң таралган әсәрләргә мөнәсәбәт кискен үзгәрә. Онытылып яткан әсәрләр кайвакытта халык күңеленә яңа юл яра. Ә кайберләре кайчандыр бик макталып, канатланып, данга күмелеп йөрсәләр дә, тиз-тиз онытылалар. Сәбәп нәрсәдә? Димәк, теге яки бу әсәрләр тарих сынавын үтә алмаганнар, халык белән бергә яши алмаганнар. Шуның өчен, әле бүген тере булган язучыларның әсәрләре хакында, аларның дәрәҗәсен, бәясен билгеләгәндә, «бу әсәр – халыкчан әсәр, тегесе – халыкчан түгел» дип әйтү һич мөмкин түгел, дип саныйм мин. Әсәрләр, авторлар, аларның

фикерләре, аларның яшәү формалары, аларның иманнары һичшиксез вакыт сынавын үтәргә тиеш.

*— Чираттагы сорау да сезнең иҗат белән турыдан-туры бәйләнешле. «Өч аршын җир» повесте моннан күп еллар элек язылса да, ул бүген генә тулы яңгыраш тапты. Бу хәлгә үзегез ничек карыйсыз?*

— «Өч аршын җир» 60 нчы еллар башында язылган иде. Мин аны Мәскәүдә укыганда бик кыска гына ара эчендә язган идем. Үземнең шул чордагы борчуларымны, мәхәббәтемне шул әсәргә кертеп җибәрергә тырышкан идем. Әсәр шактый катлаулы язмыш кичерде. Берәүләр аны бик каты күтәреп алды, ул русча журналда һәм китап булып та басылып чыкты. Ә татарча исә менә 20 елга якын аны китап итеп чыгармыйча тоттылар. Вакытында мин аңа борчылган идем, ләкин заманнар үтә торгач, менә үзем олыгая башлагач, яши-яши, чын күңелдән ясалган гадел кешеләр, чын күңелдән язылган чын әсәрләр югалып калмыйлар, дигән бер фикергә килдем. Һәм хәзер, дөресен әйткән вакытта, «Өч аршын җир»нең бүгенге көндә яңгыраш табуына мин бер яктан куанам да. Соңгарак калып булса да, ул үз вакытында килеп чыкты.

*— Аяз Мирсәетович, әлеге повесть, әйткәнегезчә, татар телендә бары 20 елдан соң гына дөнья күрә. Моның сәбәбе нәрсәдә дип уйлыйсыз?*

— Моны аңлату бик җиңел, минемчә. Безнең әдәбият өчен, гомумән культурабыз өчен җавап бирергә тиешле даирәләрдә шактый тар күңелле иптәшләр утырды ул чагында. Алар татар әдәбиятын, татар драматургиясен, гомумән татар сәнгатен бер тар юлдан гына алып барырга уйладылар, һәм шул юлга гына өндәделәр дә. Мәсәлән, ерак барасы түгел. Ул елларда «татар прозасы — бары тик эшчеләр прозасы» дип кенә игълан ителде. Эшчеләр темасына язган язучылар дәрәҗә алып, абруйлы булып макталып йөрделәр. Ә «татар поэзиясе» — «гел солдат поэзиясе» генә ул, дип игълан ителде һәм шул темада, шул сферада туган әсәрләр алгы планга чыгып, макталып йөрделәр. Әлбәттә, эшчеләр турында да язырга кирәк. Шигърияттебез солдат тормышына да борылып карасын, ләкин менә шул тарайту һәм яшь язучыларны, әле

ныгып килмәгән яшьләрне бары тик шул юлга гына кертеп җибәрү кемнәрнедер абындырды, кемнәрнедер сөрлектерде, кемнәрнеңдер иҗатларын һичшиксез тарайтты. Һәм аның зарарын әле без бүгенге көндә дә татыйбыз.

— *Бу сорау бүгенге көнебезгә карата. Хәзер хәбәрдарлык бар кешегә дә сүз әйтергә мөмкинлек бирде. Бу, билгеле, яхшы күренеш. Дистә еллар буе бәйдә торган телебез чишелеп китте, шуның белән тормышта булган тискәре күренешләргә каршы кискен көрәш ачылды. Хәбәрдарлык акны — ак, караны кара дип әйтергә мөмкинлек бирде. Ләкин шуның белән беррәттән, мондый мөмкинлектән файдаланып, без барыбыз да тәнкыйтьчеләргә әйләнеп китмәдек микән?*

— «Гласность» — хәбәрдарлык — безнең илдә генә түгел, чикләребезне үтеп, бөтен дөньяга, яңа сүз булып, яңа эчтәлек алып, набат булып яңгырый. Кирәкле сүз, бик вакытлы калкып чыккан сүз. Дөрес, монда бер нәрсәне бик нык уйларга кирәк. Бөтен кеше тәнкыйтьли, бөтен кеше тәнкыйть сүзе алып газеталарда чыгыш ясый, радиоларда күренеп китә, телевидениеларда ялтырый. Монда мине уйландырган бер нәрсә бар, әле бөтен кеше дә үз сүзен әйтә микән? Һәм, гомумән, без үзебез фикер йөртә алабыз микән? Һәм монда да, ялгышып китеп, тагын кеше җырын гына җырламыйбыз микән? Торгынлык елларында бик рәхәт яшәгән, рәхәт кичергән, эшләмичә генә ашарга гадәтләнгән, дәүләтнең байлыгын иркенләп үз файдасына гына тоткан, үз мәнфәгатен генә күзәткән кешеләр дә шушы көннәрдә «гласность» дип, «хәбәрдарлык» дип, шушы торгынлык елларны каһәрләргә керешмәделәрмени? Мисалга әдәбиятны гына алыйк. Безнең бар тәнкыйтьчеләребез. Шушы 15–20 ел эчендә әдәбиятның алдынгы тенденцияләрендә һәрвакыт киртә корып килгән тәнкыйтьчеләр булмадымени, уйларга һәм уйланырга өндәгән әсәрләрне кара буяу белән манып, дөреслекне әйтергә тырышкан язучыларны изәргә тырышкан тәнкыйтьчеләр булмадымени? Бүгенге көндә алар да атылып чыгалар трибуналарга. Һәм әле башка кешеләргә караганда алданрак атылып чыгалар. Һәм «нәкъ менә без — үзгәрешнең яклаучылары, без моны күптән көткән идек» дип аваз салалар. Шуның өчен тәнкыйтьнең нинди булуына гына түгел, тәнкыйтьнең

кемнән һәм ни өчен чыгуына да игътибар итәргә кирәк, дип уйлыйм мин.

– *Бүгенге көндә язучы буларак та һәм гомумән гражданин буларак та сезне тормыштагы нинди проблемалар борчый?*

– Бүгенге көндә мине иң борчый торган нәрсә – ул кеше проблемасы. Үзебез шаһит, без бит сугышка кадәрге елларны хәтерлибез. Кешеләрдәге күтәрелешне, энтузиазмны хәтерлибез, кешеләрдәге бердәмлекне беләбез. Культ еллары һәм торгынлык еллары безнең кешеләрнең инициативасын үтереп бетерделәр. Кешеләр үзләренең көчләренә ышанмый башладылар. Кешеләрнең хезмәткә, табигатькә, бер-берсенә мөнәсәбәтләре үзгәрде. Менә без гел «эчкечелек» дип сөйләшәбез. Эчкечелеккә каршы көрәшергә кирәк, дибез, үгетлибез, җәзалыйбыз, штрафлыйбыз. Ләкин еш кына без эчкечелекнең социаль нигезләрен ачарга җөрьәт итмибез. Эчкечелек шулай ук социаль күренеш буларак соңгы елларда гына җәелеп киткән икән, аның бит мәгълүм сәбәпләре дә бар дигән сүз. Алдан ук әйтеп куям: мин берничек тә эчкечелекне акларга да, аны хупларга да җыенмыйм. Ул безнең рухыбызга, тормышыбызга, экономикабызга гаять зур авырлык, четерекле авырлык китергән зур, усал бер күренеш булды. Ләкин бу күренешнең нигезендә дә әнә шул тормыштан канәгатьсезлек ятмый микән? Социаль тигезсезлеккә пассив кына протест ятмый микән? Менә шушы торгынлык елларында йокымсыраган акыллы кешеләрне ничек уятырга хәзер? Аларда хезмәткә мәхәббәтне ничек тәрбияләргә, эшчене ничек итеп тагы да югары күтәрергә, аңа дәрт өстәргә? Аның аңлы гражданин булуына ничек итеп ирешергә? Анда политик активлыкны ничек тудырырга? Менә мине иң борчыган мәсьәләләр шулар. Без политик акцияләр вакытында, җыелышларда, бәйгеләрдә үзебезнең фикеребезне бөтен тулылыгы белән халык арасына чыгарырыга күнекмәгән. Халык ничектер куркып, посыбрак калган. Әле хәзер дә бу үзгәрешләргә ышанып бетүчеләр булган кебек, ышанып бетмәүчеләр җитәрлек бит. Әле алар үзгәрешләргә шигәеп кенә карыйлар. Әй, булды инде мондый хәлләр, башладылар да ташладылар, тагын шул ук замана кайтыр, тагын шул хәлләр туар, дип куркып уйлаучылар да бар. Безнең төп бу-

рыч – үзгәрешләргә коры мәдхия уку гына түгел, безнең төп бурыч – бөтен көчебез, бөтен барлыгыбыз, бөтен дәртебез, яшәешебезнең мисалы белән әнә шул үзгәрешләрне ныгыту, аларга киң юл ачу һәм үзгәрешләрне тоткарлаучы, үзгәрешләргә киртә булып яшәүче пассив кешеләрне юлыбыздан алып ыргыту. Менә хәзергә иң кыены, минемчә, шул.

*– Аяз Мирсәетович, бүген без шәхес культы турында да күп сөйлибез. Шәхес культы хакында кемнәндер ишетеп белгән кешеләр дә сөйли, китаптан укып белгәннәр дә һәм үз башыннан кичергән кешеләр дә язып чыгалар. Шулай ук ул сезнең язмышта да кара эзен калдырып китте. Ул заманны сез ничек бәялисез?*

– Менә кайвакытта «ни өчен инде Сталинның шәхес культын купайтасыз, нигә ул турыда кабат-кабат кайтып сөйлисез» дигән сораулар ишетергә туры килә. Әгәр илдә бер Сталин культы гына булса, аны халык алдында ачып салу, аның тамырын ачып күрсәтү бик җиңел булыр иде. Ул шулкадәр бер-берсенә тыгыз бәйләнгән эреле-вaклы культларны тудырды бит Сталинның шәхес культы. Райком секретаренең үзенең культы бар иде, колхоз председателенең үзенең культы, югары даирәдәге совет партиясе даирәләрендә эшләүче иптәшләрнең дә үз культлары булмадымени?! Әйтик, шул ук Кунаевлар, Рәшидовларның культлары юк идемени. Аларга ияреп, бик күп уртакул, түбәнге җитәкчеләр дә үз культларын тудырмадылармени? Хәтта бик кечкенә төркемнәр арасында да без кемнедер күтәрергә һәм шул кешенең күләгәсенә ышыкланып яшәргә күнекмәдекмени? Культ булу, аңа Аллага табынган шикелле табыну, сукырларча инану безне иркен фикерләү хокукыннан мәхрүм итте. Культ безнең йомшак характерлы кешеләрне сүзсез буйсынырга мәҗбүр итте. Менә газеталарда соңгы көннәрдә һәм шушы бер-ике ел эчендә Лысенко турында бик күп материаллар басылды. Нинди акыллы безнең бөек галимнәребезне – Вавиловлар[1]ны һәлак иткән хәрәкәт. Әле аның нәтиҗәләре, аның сөреме бүген тәмам беттемени? 60 нчы еллар башында атаклы рус язучысы Юрий Черниченконың «Рус бодае» дигән бик зур мәкаләсе басылып

[1] Николай Иванович Вавилов (1887–1943) – генетик, ботаник, селекционер, географ. 1941 елда кулга алына һәм атарга хөкем ителә. 1955 елда реабилитацияләнә.

чыккан иде, «Новый мир» журналында басылды, 1962 елның 11 нче санында иде, ялгышмасам. Шунда ул «Вавиловның башы киселгән көнне биология фәне безнең илдә бер башка түбәнәйде» дигән иде. Шундый акыллы кешеләрнең зиһене томаланып, башлары киселеп яшәгәндә, безнең тормышның алга барышы тукталып кына калмады, бик күп авыр елларга артка алып ташланды. Менә культның төп авырлыгы: ул безнең үсешне туктатты, аны бик нык артка сөйрәде.

— *Әңгәмәнең темасын бераз читкәрәк борып, тагын бер сорау бирәсем килә. Ул да булса татар китабының язмышы турында. Бу хакта язучы буларак нәкъ менә сезнең фикерләрегезне ишетергә теләр идек.*

— Татар китабы язмышы турында сүз чыккач, татар китабын өйрәнүгә бөтен гомерен багышлаган тиңдәшсез галимебез Әбрар Кәлимуллинны телгә алмыйча үтеп китә алмыйм. Татар китабының тарихи язмышына багышлап, Әбрар Кәлимуллин искиткеч кыйммәтле, мәгънәле, бай фактик материал туплаган китапларны бастырып чыгарды. Татар китабының язмышын гасырлар дәвамында билгеләде, һәм инде без, киләчәккә күз салганда, татар китабының үткәндә кичергәннәрен ачык белеп эш итәргә тиешбез. Менә берәүләр «тел бетә, татар телендә китапларны укучылар елдан-ел кими, сирәгәя» диләр. Мин үзем бу җәһәттән пессимист кеше түгел. Мин татар китабының бүгенгесенә дә, киләчәккә дә якты күз белән карыйм, аның язмышына ышанам. Бу ышанычны миңа нәкъ менә бүгенге көннәрдә башланып киткән үзгәреш чоры бирә. Үзгәреш чоры бер экономикада гына калмаячак бит, социаль җирлектә дә ныгый барачак. Әле аның нинди бәрәкәтле үзгәрешләргә китерәчәген бүген күзаллап бетерә алмыйбыз. Әле без бүген күбрәк үткән көннәр турында сөйләшәбез, бүгенге көннең четерекле, катлаулы мәсьәләләрен ачарга тырышабыз. Алдагы тормышыбызны иркен, хөр фикерле, заманча кешеләр билгеләячәк, дип ышанам мин. Һәм алар тормышның бөтен фактларына үзенең мөнәсәбәтләрен ачык итеп билгеләгәндә, татар китабына мөнәсәбәттә үзенең ачыклыгын табар, ул яшәр һәм совет халыклары әдәбияты арасында үзенең лаеклы урынын бервакытта да югалтмас, дип ышанам.

— *Сез – социолог түгел, язучы. Шулай да ничек уйлыйсыз, хәзер татарча китапларны укучылар артамы әллә киресенчәме?*

— Чыннан да монда ниндидер социологик тикшеренүләр таяныч булмаган хәлдә, мин бары тик үз хисләремнән чыгып кына фикер йөртә алам. Әлбәттә, соңгы елларда татар китапларына караш шактый үзгәрде, укучылар саны кимеде, бу – бер яктан шулай. Чөнки аның шактый нигезле сәбәпләре дә бар. Безнең тормышка, луылдап, телевидение килеп керде. Кешеләр бик күп төрле каналлардан башка информацияләр ала башладылар. Китап укырга аерым категориядәге кешеләрнең вакытлары калмый да башлады. Ләкин бу язмыш бары тик татар китапларына гына карата түгел бит. Менә күптән түгел генә, моннан бер айлар чамасы элек, телевидениедан Ленинградта 9 нчы сыйныфта укучылар белән әңгәмә булып алды. Ленинградта укучы егетләргә һәм кызларга мондый сорау куйдылар: сез Бондаревны, Распутинны һәм Астафьевны беләсезме? Ленинград мәктәбенең 9 нчы классында укучылар бүгенге көндә рус әдәбиятының үзәгендә торган гаять кызыклы шәхесләрнең берсен генә – бары тик Бондаревның гына исемен атый алдылар. Анда да бер егет, «менә мин аның романы буенча куелган фильмны караган идем» дип кенә җавап бирде. Залда утыра торган 30–40 кешедән берсе дә Распутинны да, Бондаревны да, Астафьевны да укымаган булып чыкты. Бу – ил буенча бара торган күренеш. Монда бер татар әдәбиятын, татар китабын һәм татар китабының язмышын башка милли китаплардан аерып алып, аның язмышы һәм киләчәге бары тик аның гына караңгыга таба юнәлгән, дип уйлау – бу бик зур хата фикер. Татар телендә укучылар хәзер дә бар, бик актив укучылар бар. Мәсәлән, безнең журналларның тиражы, яшьләр газетасының тиражы арту, «Азат хатын» журналының искиткеч популяр булуы һәм үзебезнең китаплар да.

— *Әңгәмә өчен бирелгән вакыт тәмамланып килә. Шулай да безнең тагын бер сорау калды әле, гадәти сорау ул. Иҗат планнарыгыз турында әйтеп китсәгез иде.*

— Мин инде байтак әсәрләр яздым, байтак пьесалар. Минем тормышым бары тик асылда язу белән бәйләнгән. Минем бәхетем дә – шул язу өстәле. Мин моннан берничә

ел элек роман яза башлаган идем, бу хакта инде мин газеталарда да язып чыккаладым. Хәзер 88 нче елда бөтен төп омтылышым, хыялым – шул романны тәмамлау. Ул шактый вакытны эченә ала. Сугыш еллары, сугыштан соңгы еллар, бүгенге көн. Бүгенге көн белән үткән көннәргә күпер ташлау. Бүгенге көннең кайбер күренешләрен ачыклау өчен шул елларга кайту. Мәсәлән, Василий Лыков[1] «бүгенге көннең бөтен катлаулы, четерекле күренешләре сугыш елларында туды» дип искәртеп үтә. Мин дә шулай дип уйлыйм. Елларны елларга тоташтыра алсак иде. Елларны елларга ялгап, шушы катлаучы чорда яшәгән кешеләрнең язмышын тулаем ачып бирә алсак иде. Үзгәрешләр чоры бит безнең барыбыздан да ышанычлы хезмәт сорый. Сүз – бер нәрсә, эш кирәк. Японнарның бер бик матур мәкале бар, алар болай ди, «караңгылыкны сүгеп яшәгәнче, бер шырпы булса да кабыз», ди. Менә мин, шушы үзгәрешләр чорына көч бирер өчен әгәр бер шырпы булса да кабыза алсам, һәм ул шырпы яктысы халыклар күңеленә барып төшә алса, мин үземнең бурычымны ниндидер бер дәрәҗәдә үтәлгән, дип санар идем.

– *Әңгәмәдә катнашуыгыз өчен рәхмәт, Аяз Мирсәетович. Эшләрегездә уңышлар телибез сезгә. Һәм барлык радиотыңлаучылар исеменнән юбилеегыз белән котлыйбыз.*

## Йәгез, бер дога![2]

*(Марсель Галиев әңгәмәсе, 1993)*

Кайнар йөрәкле шәхес иде ул. Күз алдында кабынып-дөрләп, ялкынын биетеп торган учак кебек иде. Безне, гадәттә, учакның ялкыны җәлеп итә, ә төптә ярсу күмерләр нинди хәлдә тетрәп-сыктап көйрәп тере сулыш ала – анысын искәрми дә калабыз.

Аның сүз күмерләре һәрдаим дөрләп китәргә әзер иде. Үткен телле, «югары көчәнештә» сөйләү рәвеше белән ул игътибарыңны урап ала, ваемсызларны да дер селкетеп, «йонын

[1] Василий Михайлович Лыков (1923–1988) – штурмлаучы-очучы, Советлар Союзы Герое (1994).

[2] Галиев М. «Йәгез, бер дога!» // Татарстан яшьләре.– 2005.– 19 ноябрь.

язып» ала торган иде. Кәефле чагында, берәр яшь язучыга игътибар белән карап торыр да:

– Их, синең урында булсаң иде хәзер!.. Сандык төбендә яткан дүрт мең дә биш йөз шигырьне алышам яшьлегеңә! – дип, иңеннән яратып кагып куяр иде.

– Их, слушай, парин, минем яшькә җиткәч белерсең әле. Алтмыш яшь – илле түгел икән шул,– дигән иде Аяз ага. Тагын ун елдан соң ул:

– Җитмеш яшь – алтмыш түгел икән шул...– дип, тагын элеккеге «егет чагын» сагынып куйды.

Хәтерлим әле, җитмеш яшьлеген «Тургай» дигән ресторанда бәйрәм иткән идек. Аяз ага ут карашлы чибәр хатыны Нәкыя апа белән түрдә, уллары – Искәндәр (тарих фәннәре докторы), Мансур (драматург), кече уллары Рашат (табиб, бизнесмен) болар бергә, табынның икенче түрендәрәк. Аяз ага, тамада тарафыннан сүз бирелгәч, торып басып, уллары, киленнәре ягына яратып, горур бер караш ташлады да:

– Менә мин татар милләтенә өч ул үстереп калдырам. Киленнәрем дә чын татар, оныкларым да, Аллаһы бирсә, татар булып үсәчәк! Кем, кайсыгыз минем кебек өч улы белән мактана ала! – диде.

Гыйбрәтле тынлык, кисәтүле, күпләр өчен үкенүле өн салынган нәүмиз тынлык сыгылып иңгән иде шул мизгелдә. Олуг язучыбыз Аяз аганың бәгырь авазы, чаң суккандай, еллар аша һаман әле күңелдә кабатланып, сискәндереп куя.

Тавышы истә, күз карашы, йөреш-хәрәкәте, хикмәтле сүзләре хәтердә, нинди дер, күзгә күренмәс өрфия пәрдәне генә аласы да...

Хәтерлим әле, Аяз ага белән редакция бүлмәсендә шактый озак сөйләшеп утырдык (һәр сүзен яздырып барган диктофонга рәхмәт!). Бу – 1993 елның 20 сентябре иде. Аяз агага ул вакытта алтмыш алты яшь булган...

– *Сезне, Аяз ага, Алласыз һәм тарихсыз проза вәкиле булып калу куркытмыймы?*

– Менә мин «Йәгез, бер дога!» дигән әсәремне тәгәлләдем. Анда сүз кырык ел элек булган вакыйгалар турында бара. Әсәрдә телгә алынган һәр кеше – чын, һәр вакыйга үз башымнан үткән! Үткәнемә һәм тарихка хилафлык кыл-

мыйча, үзем кабул иткән дөреслекне сурәтләргә омтылдым. Чөнки кеше зурмы-кечкенәме, аның тарихка үз мөнәсәбәте, үз аршины бар. Миңа бу хатирәләрдән котылырга кирәк иде. Чөнки хәтеремнең иң якты еллары (22 яшьтән 28 гә кадәр) Сталин зоналарында, төрмәләрдә үтте. Ул темага бик күп авторлар, үзләренең ноктаи-назараларыннан чыгып, бәя бирделәр, һәртөрле жанрда язып чыктылар. Мин инде язмам дигән идем. Ләкин, уйлый-уйлый, шундый нәтиҗәгә килдем: мин булган лагерьлар турында әле беркемнең дә язганы юк. Чөнки андый типтагылар 1948 елда гына төзелде. Без соңгы дулкынга эләктек. Шушы лагерьда үткәннәремне, кеше булырга ярдәм иткән, күземне ачкан бик күп олпат ирләрне әгәр мин язып ачыкламасам, бу дөнья турындагы фикерләремне укучыга чыгармасам, әсәрләремнең төбенә төшү кыен булыр иде. Бу роман минем киләчәгемне түгел, ә үткәннәремне билгели. Сент-Экзюпери әйтә: «Мине язганнарымнан эзләгез»,– ди. Гади, һәркем башына килә торган фикер. Ләкин, менә тарихи шәхес, философ, мәшһүр язучы әйткәч, ул ышанычлырак...

– *Үзебездә туган фикерне авторитетлар җилкәсенә салырга тырышу гадәте безгә каян килә?*

– Без бит үз фикерләребезне кемнәндер оялыбрак әйтәбез. Чөнки безнең беребезне дә татар халкының да, дөнья халкының да әле укытучы-остаз итеп, акыл иясе итеп танығаны юк. Безнең татар әдипләренең гомер юлларын әсәрләренә карап фикер йөртү кыен. Затлы кешеләребез хакында истәлекләр басылып чыга, ләкин алар искиткеч ярлы, фәкыйрь. Чорыбызның иң зур, фаҗигале язмышын кичергән Салих Сәйдәшев турындагы истәлекләрне генә карыйк. Ул китап әллә кайчаннан бирле кибет киштәләрендә тузан җыеп ята. Әгәр без шушы бөек шәхесне ача торган нәни генә дәлилләр белән беркетеп, кеше җанына, аңына үтеп керерлек искәрмәләр белән чыгарган булсак, бу китап тормыш дәреслеге булып хезмәт итәргә тиеш иде бит. Чөнки XX гасырда Сәйдәш кебек талантлы, аның кебек бай рухлы һәм татар җанын аркылыга-буйга, түбәннән югарыга аңлаган шәхес тагын бармы? Ул – безнең милли каһарманыбыз. Бу югары сүзне без Тукайга карата гына әйткән идек. Халыкка маяк,

күңел серләренә юлдаш булырлык, телне-моңны, бөтенлекне аңлаган ике милли каһарман бер гасырга җитә, дип уйларга кирәк.

— *Чор, төшенчәләр үзгәрә барган саен, бу шәхесләр әле яңа яктан ачылачаклар. Дөресен әйткәндә, әгәр тормыш элеккечә тигез генә барса, Тукайны революционер, коммунист итәргә дә күп калмаган иде бит...*

— Тукай каршылыклы шәхес булмаган, дип кем әйтә ала?! Әлегә без аны гел уңайга гына сыпырып тордык. Туры Тукай, дибез. Аның хаталары булмаганмыни?! Үз замандашларына карата мөнәсәбәтләрдә «балаларча суллык авыруы» белән авырмаганмыни?! Тукай, миңа калса, үзенең каршылыклы булуы белән дә бөек. Аның ясаган хаталары, кылган гамәлләре — уңаймы алар, тискәреме — безнең өчен гыйбрәт, сабак. Ә Сәйдәш?.. Аны изеп таптаган, иҗатын буып торган кара ташлар аз булганмыни?!

— *Күптән түгел теплоходта без Әстерханга төштек. Анда зур галимнәр, Әмирхан ага кебек аксакаллар катнашкан дискуссия вакытында Миргазиян Юныс: «Бездә, революциядән соң, гомумән, әдәбият юк!» — диде. Мондый максимализм бездә студент чакта бар иде, ул чакта килешә иде. Моны бит яше алтмыштан узган әдип чын күңеленнән әйтте.*

— Бер ул гына андый фикер йөртми. Радиодан чыгышларының берсендә, әле шушы елда, Мөхәммәт Мәһдиев тә, «революциядән соң татар әдәбиятында бер генә күренекле әсәр дә юк» дип раслап чыкты. Бу нилектән туа? Талантлы язучылар булган кебек, халыкның талантлы укучылары да булырга тиеш... Телисеңме-теләмисеңме, әдәбиятның югарылыгын, аның базар бәясен, әгәр шулай әйтергә ярása, укучы үзе билгели. Дөрес... Татар әдәбиятының туксан биш проценты бүген авылга хезмәт итә. Татарның зыялы, әзерлекле укучысы аз. Әдәби телнең нечкәлекләрен белеп язган Әмирхан Еники. Мөхәммәт Мәһдиев, Гариф Ахунов кебек язучыларның тел байлыгыннан күпме процент татар файдалана? Безнең әдәбиятның зур ялгышы — ул халыкка ярарга тырыша. Аның алдында тез чүгә, үрмәли, вагая. Ә бит язучылар төрле зурлыкта булган кебек, укучының да кабул итү дәрәҗәсе бердәй түгел. Миргазиян Юныс татар

әдәбияты турында хөкем чыгарганда, моннан мең ел элек башланган Европа әдәбиятлары белән чагыштырып карый. Ә бер уйлап карасаң, безнең проза бик яшь әле, аңа йөз ел гына тулып килә. Әдәбиятны караңгыга кысрыклап кертү җиңел ул. Дөнья әдәбияты классиклары, без хаклы рәвештә ярата торган шәхесләр белән чагыштырганда, әдәбиятыбыз түбәндә түгел... бары тик яшь булып кына кала. Бер генә әдип тә, бер әдәбият та үз халкының дәрәҗәсеннән югары сикерә алмый...

— *Киләчәктә Европа һәм Шәрык философиясен яшьтән өйрәнгән, Коръән, Таурәт, Инҗилләрне яхшы белгән фикри әзерлекле яшь талантлар әдәбиятка килерме?*

— Әгәр якын елларда татар бетмәсә... Чын татарлар туу өчен тагын ике-өч буын үтү кирәк. Безнең бүген исламиятнең бөеклеген аңлатып бирер галимнәребез юк. Диннең өстә яткан кануннарын аңлатудан башка тирәнгә керә алган шәхесләр күренми. Дин әһелләре, чыгыш ясаганда, үз сүзләренең кемгә, нинди катлау кешеләренә юнәлдерелгәнен ачыклап бетермиләр. Әлбәттә, динсез булмый. Дин — милләтнең, халыкның бөтенлеге сагындагы зур көч! Милләт өчен уртак дин алган халыклар гына дәүләтчелеккә ирешкәннәр. Динле, дәүләтле булу — тарихның бөтен юлларында бәхет саналган... Безнең милләтебезнең эчке ресурслары хәзер юкарган чак...

— *Алда бер дә өмет күрмисезме?*

— Без — җиде миллионлы халык, дибез. Кайберәүләр аны егерме миллионга җиткерә. Бу бит — миф. Катнаш гаиләләр күбәя барган чорда нинди миллионнар булырга мөмкин! Алдырма син сан белән. Алдыр эш-хезмәт белән. Бер генә мисал: безнең Вил Мирзаянов[1] дигән егетебез дөнья каршында үзенең көрәше, максатының ачыклыгы белән дан казанды. Бүгенге көнгә кадәр бу шәхеснең иманын, ул иманның ныклыгы нигезләрен ачып бирә алганыбыз бармы? Гомумән, без милләткә хезмәт итә торган шәхесләргә бәя биреп үтмибез, ныгытмыйбыз. Уртак каһарманнарыбызны күтәрә белмибез. Башкортларны гына алыйк. Салават Юлаев белән алар күпме еллар яшиләр. Шундый зур, якты шәхесләр милләтне җылытып торалар. Алар — милли тамырларга һәрвакыт көч

[1] Вил Солтан улы Мирзаянов (1935) — химия галиме.

биреп тора торган дым... Югыйсә, бездә ул чорның Бәхтияр Канкаевлары, Батыршалары юкмы? Тарих алга барсын өчен, шәхесләрдән калыккан баганаларга гына күпер кагып була. Безнең уртак милли батырларыбыз бармы бүген?

– *Муса Җәлил?*

– Ул – ачылып беткән шәхес түгел... Мин Җәлил һәм аның иптәшләре хакында шик-шөбһә уятырга теләмим. Яшьләрне тәрбияләүдә үз вакытында аларның роле югары булды. Ләкин... милли геройлармы алар? Татарның киләчәге өчен һәлак булдылармы? Уртак ватан өчен һәлак булулары белән тарихта калырлар, әлбәттә, әгәр килер заман яңа дәлилләр табып, аларның батырлыгын «батырлык» дип таныса...

– *Сез, Аяз ага, юл йөрергә бик яратасыз. Соңгы вакыттагы тәэсирләрегез нинди?*

– Авылларның рәвеше үзгәрә. Мәчетләр салына. Ләкин бу изге эшкә күп җирдә ашыгып, алдан уйлап бетермичә тотыну сизелә. Мәчетләрнең чын архитектура үрнәге булып гасырларга калачак дип төзелергә тиешлеген онытмасак иде.

– *Моннан ун еллар элек без Сезнең белән Испаниягә барган идек. Ун чакрым биеклектән очкан самолет канатына тияртимәс калган Альп кыяларына карап шәраб эчкәндә, Сез: «Бу мизгелне бүтән кабатлап булмый»,– дип әйткән идегез. Их, шуны тагын бер кабатлыйсы иде, дигән үкенечле мизгелегез бармы дөньяда?*

– Юк. Тәкъдир язган һәр мизгелдә үтәләсе үтәлгән, эшләнәсе эшләнгән. Әйтмим, һәрчак хак юлдан гына баргpanмындыр, дип. Без бит – бәхетсез заман җимешләре. Шулай булдык, тегеләй булдык, дип никадәр генә күкрәк какмыйк, гасырга хас хаталар бөтенебездә бар. Берәүләр бүген ашыгып-ашыгып үзгәрергә маташа, икенчеләр кабат ялган юлга баса... Без яшәгән ил шундый булды ул: ак киемнән, корымлы казан янында йөреп, тапсыз калу мөмкин түгел иде.

Кичергән мизгелләргә бәя дә үзгәрә икән шул. Менә ни өчен үткәннәргә кайтып, кабатланасы килми.

– *Сталин чорында палачлык, доносчылык хөкем сөргәндә, кем нинди юл белән исән калганлыгы хакында хөкем йөртергә безнең буын кешеләренең мораль хокукы юк, дип саныйм. Бүген*

*шул мәхшәр кабатланса, совет чорында тәрбия алганнар тагын да явызрак, тагын да түбәнчелеккә төшәселәренә шикләнмим. Бу дәверне хәтерегездә кузгатканым өчен гафу үтенәм, әмма бер сорауны бирмичә кала алмыйм. Сезне саткан, төрмәгә утырткан кешене беләсезме? Аны очраткач исәнләшәсезме?*

– Хәзерге мәгълүматларга таянганда, ул чорда һәр өч кешенең икесе теге яки бу күләмдә җәзалау органнары белән бәйләнештә торган. Катлаулы, авыр чор! Мине төрмә сукмакларына этәргән кешеләрне моннан ике ел элек кенә белдем. Бар – исәннәре, бар – күздән югалганы... Барчасы белән күрешеп-сөйләшеп йөрим. Аерым шәхесләргә караганда, чорны ныграк гаеплим. Беләм, ул гаеплеләр шушы елларда тәүбәгә килде. Тәүбәгә килеп, күңелеңне сафландыру – үзе дә бер батырлык ич. Тәүбәгә килү (покаяние) – һәртөрле дини өйрәтүләрдә күңел байлыгына ия булу түгелмени! «Казан утлары»ның 10 нчы санында басыла башлаган «Йәгез, бер дога!» дигән роман-хатирәмдә мин хәзерге заманның катгый сорауларына үткәндәге гыйбрәтләр белән җавап бирергә тырышам.

– *Сезнең дә намус-вөҗданыгызга «күләгә төшерергә» тырышкан имеш-мимешләр, хәтта матбугатта язмалар да булды. Моңа каршы Сез ачыктан-ачык җавап бирмәдегез шикелле?..*

– Кешеләргә гаеп ташлау, шик-шөбһә белдерү – көнчелек галәмәте. Әгәр мин әдәбиятта кайсыбер уңышларга ирешә алмаган булсам, ай-һай, мондый кара хәбәрләр шытып чыгар иде микән... Миңа таш атып калкынырга тырышкан кемсәләрне эзәрлекләргә дә, үч алырга тырышырга да җыенмыйм. Югарыда телгә алынган романым әнә шул бәндәләргә җавабым да булыр. Язмышым турындагы хөкемемне йомгаклау сүзләрен мин замандашларыма шунда тапшырам.

– *Җитмеш ел буена илдә-көндә барган вакыйгаларның асылына без соңгы елларда гына төшенә башладык. Хәзер күп нәрсә ачылды. Соңгы берничә ел эчендә артка, егерменче елларга кадәр кайтып, коточкыч күп мәгълүмат алдык. Әгәр ул мәгълүматлар табигый эзлеклелегә белән кереп барган булса... Сезнең «Балта кем кулында?» дигән романыгыз башкача, тыныч-сабыр күңел белән язылмас идеме? Сез, читлектән кинәт иреккә чыгарылган арыслан кебек, бөтен нәрсәне таптап, изеп, бәргәләнеп, ба-*

*рысын да тизрәк әйтеп калырга ашыккансыз сыман тоелды бу романыгызда.*

— Ул романны мин моннан ун-унбиш еллар элек язарга уйлаган идем. Әлбәттә, сюжеты гадирәк иде, син әйткәнчә, тынычрак агышлы иде. Ләкин әсәр үзе өлгерде һәм мине өлгертте. «Балта кем кулында?» — минем иң җитди әсәрләремнең берсе дип уйлыйм. Монда минем чорга, халкыма мөнәсәбәтем чагыла. Балта кем кулында? Балта ленинизм, совет режимы кулында! Бу режим ике катлауны да имгәтте. Югары катлауны чамасыз-чиксез байлыгы белән, бернинди җаваплылык тотмый торган иркенлеге белән, бөтен бозыклыкка юл ачып, талауга, халыкны мыскыллауга йөз тотып имгәтте. Ярлы-ябагайларны исә ач тотып, салымнар белән сытып, кешелек хокукларын тартып алып имгәтте. Совет режимы аста да, өстә дә гарипләрне генә тудырды. Мин соңгы әсәрләремнең бөтенесендә дә шушы режимның татар халкын ничек изүе, талавы хакында фикер йөртәм. Милләтнең һәлакәте алда әле... Без гел инкыйраздан куркабыз. Ә бит инкыйраз булып узды. Тагын нинди инкыйраз көтәргә мөмкин! Татар кызларының кырык проценты чит милләт егетләренә кияүгә чыга. Татар егетләренең кырык проценттан артыгы чит милләт кызларын алып йөзләрен югалта. Бер Наҗар Нәҗми[1] авылыннан гына да 26 татар кызы Үзбәкстанга кияүгә чыгып, соңгы берничә ел эчендә үзбәк халкын күпмегә баетты! Без алга карый белгән милләт түгел. Менә сиңа бер кыйсса: Ленинградның Товстоногов театры берничә ел элек Япониягә гастрольгә бара. Шуннан кайткач, күренекле актер Олег Басилашвили шундый бер хикмәтне сөйләде. Токиодан 75 чакрымда бер югары мәктәп бар икән. Анда Япониянең булачак галимнәре, эшмәкәрләре, министрлары, икътисад хуҗалары, кыскасы, сайлап алынган балалар укый икән. Шушы мәктәпнең ректоры Ленинград театрын расходланып чакырта, ике спектакль куйдырта. Шәкертләр бик матур каршы алалар. Басилашвили ректордан сорый: «Менә без

[1] Хәбибнаҗар Нәҗметдин улы Нәҗметдинов (Наҗар Нәҗми, 1918–1999) — татар-башкорт шагыйре, Башкортстанның халык шагыйре (?), БАССРның С. Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1972).

сезгә ят булган урыс тормышыннан «Ат тарихы»[1] һәм «Ваня агай»[2] спектакльләрен күрсәттек. Сезнең укучыларга моның нинди файдасы бар?» Ректор: «Әгәр шушында укыган мең җиде йөз укучының, дистә еллар үткәч тә, бу спектакль исенә төшеп, күңелендә мәрхәмәт очкыны кабынса, безнең бүгенге эшебезнең нәтиҗәсе булган», – ди. Менә япон ничек алга карый! Авылда калып, дуңгыз, ат койрыгы борып кына алга китеп булмый. Шәһәр әлегә татар шәхесләрен бирми. Канында, җанында милли рух юк икән, андыйларны мин «ямаулы татарлар» дип атыйм. Ана карынында ук Сәйдәш моңнарын, «Ак бүре» әкиятләрен тыңлап үсмәгән татар беркайчан да чын татар була алмый. Халкына мәхәббәт рухында тәрбияләнмәгән кешедән ничек инде милли каһарман чыксын! Ләкин... Татарның коесы корыган, чишмәсе агышын туктаткан, дип әйтергә җыенмыйм. Хәзерге көндә милләтне ныгытырга мөмкинлекләр бар.

– *Соңгы елларда мәйданнар шаулый. Нindidер партияләр оеша, нindidер көрәшчеләр сәхнәгә чыга. Сәяси эстрадага чыгучы көрәшчеләргә Сез ышанасызмы?*

– Юк! Берсенә дә! Үзләренә дә ышанмыйм! Сүзләренә дә ышанмыйм! Теләсә нәрсә әйтсеннәр. Башта мин Минтимер Шәймиевкә дә ышанмадым. Ул бит партияле кеше. Әле дә ул партия сафларыннан чыкмаган, әгъзалыгын туктатып кына тора... Бүтән җитәкчеләр дә шулай. Ләкин Минтимер Шәймиев бүгенге көндә милләтебез язмышы хакында уйлап эш итә. Ул моны хәл итеп бетерде, бөтен капкаларны ачты, дип әйтергә җыенмыйм. Әмма... кылган гамәлләренә караганда, ул дөрес кыйбла тота. Милли лидер булып йөрүче нindidер маймылларга, Шәймиевне Җаһар Дудаевка[3] алыштырыйк, дип йөрүче бушбугазларга ничек инде ышанасың! Без бу милли нигилистлардан, бушкуык экстремистлардан арынсак, милләтебез, шәт-иншалла, тарихта үз миссиясен үти башлар.

---

[1] Л. Толстойның «Холстомер» повесте буенча спектакь (1975, реж. Г. Товстоногов).

[2] А. П. Чеховның «Дядя Ваня» пьесасы буенча спектакль (1986, реж. Г. Товстоногов, Е. Макаров).

[3] Джохар Мусаевич Дудаев (1944–1996) – чечен сәясәт эшлеклесе, Чечня Республикасының беренче президенты (1991–1996).

*— Хәтерлим әле, Сибгат ага Хәким исән чак иде. Аның шигыренә язылган хикмәтле бер җыр бар иде бит әле:*

*Су буенда өянкеләр,*
*Минем дә җитте бугай бит*
*«Картайдым» дияр көннәр...—*

*Шушы җыр яңгырый башлауга, Сезнең күзләрдә яшь күренә. Нинди каты бәгырьле дип уйлаган, җыелышларда «тагын кемне сүгеп ташлар микән» дип, тетрәндереп торткан Аяз ага еласын әле. Мин моны беренче кат күргәндә бик гаҗәпләнгән идем. Аннары ничә тапкырлар шушы җыр җырланганда Сезнең күңел йомшауга шаһит булдым. Башка җырга алай ук чишелеп китмисез бит, сәбәбе нәрсәдә икән?*

— Аны аңлатып булмый. Бу — нindидер сер, әлбәттә. Сибгат аганың 60 еллык юбилеенда Рөстәм Яхин мине чакырып алды да: «Аяз, син бит әле карт та түгел, нигә шулкадәр бу җырны бәгыреңә үткәреп кабул итәсең?» — дигән иде.

*— Сезнең хакта «күп нәрсәдән хәбәрдар, күп нәрсәне алдан белеп тора» дигән легендалар йөри. Әйтик, Аксак Тимернең кайсы аягы аксак икәнне, Маргарет Тэтчерның иртәгә иртән иренә нәрсә пешерәсен... Аяз ага, әйтегез әле, якын араларда нинди кызыклы вакыйгалар булачак?*

— Безнең бер чордашыбыз минем һәм минем берничә яшьтәшем турында олы бер шикаять язып җибәрәчәк. Исемен куеп тормас, «информатор» дип кенә тамга салыр. Коммерция оешмалары безнең Язучылар йортына бармакларын тыктылар. Якын араларда бу йортны алар тартып алып, язучы-әдипләрне урамда калдырачаклар.

*— Боларның чынга ашмавы өчен, Аяз ага, йәгез, бер дога!..*

## Яшьлек дусларым[1]

*(Марат Әмирханның[2] әңгәмәсе, 26 декабрь, 1993)*

*Кадерле дуслар!*

---

[1] Марат Әмирханның Аяз һәм Нәкыя Гыйләҗевалар белән әңгәмәсе (26 декабрь 1993 ел) // Сөембикә.– 2002.– №4.– 30–31 б.

[2] Марат Әмирхан улы Әмирханов (1933) – татар язучысы, журналист, публицист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1987).

*Татарның телендә бер сүз: «яшьлек дустым, яшьлек дустым, яшьлек дусларым!» Тора-бара, яши-яши, тормышның төрле чарпалышларында, ыгы-зыгылар арасында дуслар әкренләп тарала. Балалар өйләнә, кызлар кияүгә чыга, яңа кардәшләр барлыкка килә һәм, әкренләп, озак еллар бергә яшәгән кешеләр дә бездән берәм-берәм ерагаялар, тора-бара бөтенләй онытылалар. Берзаман Займищеда, җәйләрнең матурында, ике-өч атна дәвамында бездә беркем дә кунак булмагач, Нәкыя әйтә: «И Аяз, безнең өлкәнрәк танышларның балалары өйләнеп, кызлары кияүгә чыгып, алар инде үзара туганлашып беттеләр, яшьлек дусларыбызның күпләре онытылып бетте», — ди.*

*Мин шуның өчен, яши-яши, бер фикердә калдым: яшьлек дуслары матур, алар белән аралашу җиңел, утырышасың, бер-береңне мактыйсың, сөенәсең, йөзләр якты, күңелләр көр. Һәм бервакыт шушы дәртле, дәрманлы дусларың бетеп киткән. Гомумән, картлык — ялгызлык чоры ул. Ләкин ялгызлык кешенең бер чорында да, бер вакытында да, бер дәверендә дә сөенеч түгел. Була, инде олыгая башлагач, адәмнең бөтен зәвыклары ачыклангач, эче-тышы мәгълүм булгач, кемдер, һич көтмәгәндә, синең чатырыңның ишеген кага, кем дип сорап тормыйсың, инде кызыксынмыйсың, ишекне ачып җибәрәсең дә: «Рәхим ит, түргә уз!»*

*Кем дисеңме — бу инде синең картлык дусларың. Мин яшьлек дусларының бәясен һич киметергә теләмим, иллә мәгәр өлкәнәйгәч табышкан, олыгайгач аралашкан дусларның аерым бер, урысча әйткәндә, ароматы, төсе, төсмере, мәгънәсе бар. Алла шаһит: без инде хәзер дуслар эзләп каядыр чапмыйбыз, безнең дуслар үткәннән, без кичергән көннәрдән, без бергә сулаган һавадан гына килеп керергә мөмкин. Менә, Марат, кадерле дустым, әгәр Ләлә булмаса, әгәр Ләлә безнең белән бер йортта, бер бакчада гомер кичермәсә, безнең балалар үзара якын аралашып яшәмәсә, без байтак еллар ризык бүлешмәсәк, Ләлә белән Нәкыя бер-берсенә тартылган дуслар булмаса, мин сине ничек эзләп табар идем икән? Без инде синең белән эчке мәҗлесләрдә катнаша алмыйбыз, син йөргән җыелышларга мин бармыйм, мин йөргән туң утырышларга син эз дә басмыйсың, чөнки син — акыллы кеше. Ә тормыш барыбер үзенекен итә, аның үз кануны барыбер тәкъдиргә язылганын китереп чыгара. Менә безнең ха-*

*тыннарның дуслыгы, безнең хатыннарның аралашулары безне монда бүген, якынаеп килгән 1994 елның бер кичендә, мул табын янында, шәп аракылар тирәсендә егетләрчә очраштырды. Карыйм, сөйләшәбез, фикер алышабыз. Синең фикерләрең йөгерек, синең фикерең ачык, иманың камил, телең төгәл. Карыйм, син мине аңлыйсың, мин дә сине аңлыйм. Аңламасам, аңларга тырышам, чөнки син миннән яшьрәк, чөнки син — иртән чаңгыга басып, Зәңгәр күлләр тирәсеннән, җәһәннәмнән, минем өчен, чакрымнарны үтеп, өч сәгать дәвамында җирне каплаган карны дөбердәтеп таптап, егетләрчә күкрәк кагып, йөрәк кагып, шәп айгырларча үткән кеше. Ә мин шул инде һаман, гадәттәгечә, машинкага кадалып, күрер-күрмәс күзем белән, томаланган зиһенем белән нидер әйтергә тырышып утырган булам. Әле ярый, дөньяда безне берләштерә торган иман бар. Бу — бәхет.*

*Иман нәрсәсе белән кадерле? Иман — бер. Һәм ул бөтен кешеләрне берләштерә ала. Аның көче зур. Һәм бүген менә шушы 26 декабрь кичендә, матур табын тирәсендә, без түгәрәкләнеп, бер йолдыз булып утырабыз. Рәхмәт сиңа. Ләләгә рәхмәт. Карчык, син дә кушылырсың, дип уйлыйм.*

Н. Г. Ничек итеп кушылмыйсың, ди, би-и-к матур итеп китереп чыгардың бит.

А. Г. Әйе, шуның өчен, без нинди генә фикердәш булмыйк, Марат дустым, без нинди генә көрәштәш булмыйк, шулай да безнең дуслыкның, безнең очрашуның, безнең танышуның һәм табышуның нигезендә безнең газиз хатыннарыбыз ята. Мин бу тостны, мин бу тәмле аракыны, әйдә әле, үзебезнең гадел, газиз хатыннарыбыз саулыгына эчеп куярга тәкъдим итәм.

*М. Ә. Инде әдәбият турында сөйләшергә дә вакыт җитте кебек...*

А. Г. Менә мин татар язучылары белән очрашам, тик алар белән әдәбият турында фикердәш була алмыйм. Бәхәсләшәбез, ләкин берсенең дә дөнья әдәбиятына таянырлык мисаллары юк, чөнки татар әдипләренең берсе дә дөнья әдәбиятын белми. Аңламый, кабул итми, чөнки татар әдәбияты бик яшь әле.

Кайчан башланган безнең драматургиябез, кайчан башланган безнең прозабыз? Без бит әле бөтенебез дә, нигездә,

чын күңелдән генә әйткәндә, XX гасыр балалары. Ә бит әдәбият инде... менә мин үземнең романымда Терентей Варроннан[1] авыл хуҗалыгында эшләүче бүленеш турында мисал китердем. Ә ул – безнең гасырга кадәр яшәгән кеше. Хакыйкать бит шул заманнардан килә. Хода шаһит, мин бүген ниндидер сүз әйтәм икән, миңа кадәр булган нинди бөек, тапкыр кешеләр булуын истә тотам. Ул – Бернард Шоу, ул – Генрик Ибсен. Ибсеннең әсәрләреннән тыш тормыш мисалы да бар. Ул үзенең бөтен яхшы әсәрләрен үз иленнән китеп, чит илдә язган. Гомумән, үз илеңдә генә иҗат итеп яшәү – ул фаҗига. Син ваклыкларга кереп чумуыңны сизми дә каласың. Николай Васильевич Гоголь егерме өч ел чит илдә яшәгән. Достоевский чит илдән кайтмаган. Тургенев гомер буе Парижда яшәгән. Ни өчен Александр Исаевич Солженицын, «мин – бөек пәйгамбәр» дип санаган һәм аңа инанган, һәм алдагы тарихта ул шулай булып калачак. Минем күрше Леня әйтә: «Аяз Мирсаедович, нәкъ унике ел элек син безгә кердең дә мондый сүз әйттең: «Рәсәйдә ике кешенең генә һәйкәле калачак, аның берсе Андрей Дмитриевич Сахаров, икенчесе – Александр Исаевич Солженицын». Шулай дигәнмен. Шулай булачак. Чөнки бу ике кеше дә – милләт каһарманнары. Милли каһарманнар. Менә милләт, милләт булсын өчен кемнәр кирәк?

*М. Ә. Гаяз Исхакый турында ни әйтәсез?*

А. Г. Гаяз Исхакый – мине бик сөендерә торган фактлар җыелмасы. Татар педагогикасының үзгәрешләрен башлап җибәреп маташкан Альберт Яхин беркөнне миңа әйтә: «Аяз, менә мин дәреслекләргә программалар төзим һәм Гаяз Исхакыйны берничек сыйдырып булмый», – ди. Мин көлеп җибәрдем, кочаклап алдым: «Ниһаять, сез тәкъдим иткән программаларга сыймый торган татар әдибе дә килеп чыккан икән. Чөнки сез, тырышып-тырышып, Шамил Рәкыйповны, Фәнис

[1] Марк Теренций Варрон (Варрон Ратинский, безнең гасырга кадәр 116 – 27 нче еллар) – Рим галиме, «Авыл хуҗалыгы» (3 китап) исемле дидактик хезмәтнең авторы.

Яруллинны[1], Кави Латыйпов[2]ны, фәләннәрне, Мөсәгыйть Хәбибуллинны программаларга кертәсез. Аларны бит аңлату бик җиңел. Совет власте өчен көрәшкәннәр, нидер эшләгәннәр». Ә Гаяз Исхакыйны аңлау һәм аңлату һәм, дөресен әйткән вакытта, безнең татар тормышының үзәгенә кертеп җибәрү – җиңел түгел. Ул – катлаулы язучы. Мин сөенәм, аның хикәяләре Бунин хикәяләреннән берничек тә ким түгел. Гаяз Исхакый, чын күңелдән генә әйткән вакытта, Бунинның шәкерте.

*М. Ә. Садри Максуди[3]га мөнәсәбәтегез ничек?*

А. Г. Тарихи шәхесләр әле байтак. Бу шәхес турында төгәл генә фикерем тәгаенләнмәгән. Аның гаҗәп талантлы кеше икәнен аңлыйм, беләм. Ләкин Гаяз Исхакый турындагы фикерем минем бик камил. Моны бер мисал белән әйтәм. Әле күптән түгел мин бер гимназиядә булдым. Шуның татар теле укытучысы һәм аларның завучы – татар теле укытучысы икенче иптәш – менә Гаяз Исхакыйның «Кәҗүл читеге»[4]н программага керткәннәр, «шуны без дәрестә берничек тә үткәрә алмыйбыз» дигәч, мин аларга бер вакыйганы сөйләдем.

«Менә минем хатыным Нәкыя ханым, татар телен бик күп еллардан рус мәктәбендә укытып, зур тәҗрибә туплаган мөгаллимә, үзенең ачык дәресенә тема итеп Гаяз Исхакыйның «Сөннәтче бабай»[5] дигән хикәясен алды. Күз алдына китереп карагыз әле, «сөннәт» сүзе – үзе генә дә балалар өчен аңлау һәм аңлату өчен шактый кыен тема түгелме? Ләкин ул шушы хикәядән татар тормышына ачкыч була алган бик күп вакыйгаларны эзләп тапты. Шуның өчен Гаяз Исхакый телгә керә икән, әле аны аңлау һәм аңлату – бары тик киләчәк бу-

[1] Фәнис Гатаулла улы Яруллин (1938–2011) – татар шагыйре, язучы һәм драматург. Муса Җәлил премиясе, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1995). «Халыклар дуслыгы» ордены кавалеры.

[2] Кави Таһир улы Латыйпов (1927–2008) – язучы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Чувашиянең И. Яковлев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

[3] Садретдин Низаметдин улы Максудов (1878–1957) – Россия һәм соңыннан Төркия сәясәтчесе, хокукчысы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе. Идел-Урал штатын кору эшендә катнашкан кеше.

[4] Г. Исхакыйның 1912 елда язылган хикәясе.

[5] Г. Исхакыйның 1911 елда язылган повесте.

ыннар эше генә. Мин сөенәм, ниһаять, татар әдәбиятында гади генә кушу-алу гамәлләре белән аңлатып булмый торган катламнар да бар икән.

*М. Ә. Сез үзегезнең яңа романыгызда Ибраһим Нуруллинның Гаяз Исхакый иҗатына карата булган мөнәсәбәте турында әйтәсез. Һәм аны «бу – Нуруллин эше түгел, бу – яшь буыннар эше» дип әйтәсез. Моңа аңлатма кирәк сыман.*

А. Г. Аңлатам. Мәктәп программалары белән тәрбияләнгән менә шушы буын укытучылары – алар нигездә Ибраһим Нуруллин һәм аның яраннарының шәкерте бит. Ибраһим Нуруллин Гаяз Исхакыйның бөек иҗатын марксизм-ленинизм кысасына сыйдырып аңлатырга тырыша. Аның төп хатасы шунда. Ул болай ди, «менә Гаяз Исхакыйның революциягә кадәрге иҗаты – безнең өчен кызыклы иҗат, ә аннан соңгы иҗатын иләктән иләргә кирәк» ди. Бу бит – ахмаклыкның соңгы чиге.

*М. Ә. Ибраһим Нуруллин – Гаяз Исхакыйның иҗатын өйрәнү кирәклеге турында обком секретарена хат язган кеше.*

А. Г. Ул хат дөрес. Мин аңа үземнең романымда да дөрес дип бәя бирәм. Ләкин ул Гаяз Исхакыйның иҗатын чикләп аңлатырга тырыша. Һәм әнә шул обком кешесенең вкусына, зәвыгына яраклаштырырга маташа. Имеш, революциягә кадәр Гаяз Исхакый бер булган, революциядән соң Гаяз Исхакый икенче булган. Ә кеше буларак, гражданин буларак, Гаяз Исхакыйның революциядән соңгы иҗаты аерата зур бәягә, зур хакыйкый дәрәҗәгә ия. Ул чор хакында Исхакый кебек дөрес сүзне әйтә алган кеше юк. Татар язучылары революциядән соң сыныш кичерәләр. Сыныш.

*М. Ә. Сез ничек уйлыйсыз, эмиграция, бигрәк тә унҗиденче елдан соңгы эмиграция, татар әдәбиятына зур зыян салган эмиграция түгелме?*

А. Г. Ул чор – эмиграциягә зыян китерү генә түгел, монда калган язучыларның да иҗатын бөтенләй ялгыш юлга кертеп җибәргән, большевизмның зарарлы агуы белән агуланган чор. Ал, Һади Такташны. Аның беренче еллардагы иҗаты – дөньядагы иң бөек әдипләрнең, иң бөек шагыйрьләрнең иҗаты белән тиң куелырлык әдәбият. Күз алдына китерик

бер «Җир уллары» трагедиясен[1] генә. Ә бара-тора Һади Такташ «Камил»[2] дигән пьесасында ВЧКны мактый, сатлык кешеләрне күтәрә. Гомумән, татар әдипләре – утыз җиденче ел фаҗигасен тырышып-тырышып әзерләгән кешеләр.

*М. Ә. Хәсән Туфанны бөек шагыйрь дип таныйсызмы?*

А.Г. «Хәсән Туфан – татар халкының бөек улы» дигән сүз – миф ул. Лагерь тормышын үтсә дә, ул гомергә Ленинны, ленинизмны мактаган кызыл булып калды. Ул «шушы дөньяның аталары булып калачак» дип, Фидель Кастроны, Иракның канлы тираны Саддам Хөсәенне атады. Шуларны мактап шигырьләр язды. Һәм гомере буе үзенең йомшак кына йодрыгын йомарлап, океан арты кешеләренә йодрык күрсәтте. Әгәр ул төрмәгә кереп, әзгә генә язмыш тарафыннан акылга утыртылмаган булса, һәм шул лагерь чорыннан шигырьләр язмаган булса, Хәсән Туфан Галимҗан Латыйп[3], Нәби Дәүли, Мәхмүт Хөсәен[4] кебек уртакул, төссез һәм нигезсез шигырьләрнең авторы буларак калыр иде. Ходага рәхмәт укысыннар, әле ярый Хәсәнне чекистлар утырткан, әле ярый Мусаны төрмәгә тыкканнар. Алар бит икесе дә «кызыл авыз» иде. «Кызыл авыз». Алыйк Фатих Кәримне! Ул бит Мусага караганда мең мәртәбә бөегрәк. Ләкин без татарлар һаман Мәскәүнең безгә кемне кем итәргә рөхсәт итмәсәләр... без һаман шул «кызыл авыз» Мусага, мин моны... Ләлә, курыкма, язып та чыктым...

## Татарстан язучыларының XII съезды алдыннан

*(Анкета, 18 февраль, 1994)*

***Анкета***

1. Язучыларыбызның XI съездан соң үткән 5 елдагы иҗатына һәм аерым әсәрләргә карата Сез нинди фикердә?

---

[1] Һ. Такташның 1921 елда язылган шигъри трагедиясе.

[2] Һ. Такташның 1931 елда басылып чыккан пьесасы.

[3] Галимҗан Шакирҗан улы Латыйпов (1912–1986) – шагыйрь. Татарстан Язучылар берлегенең балалар әдәбияты секциясе эшенә җитәкчелек итә, профсоюз комитеты рәисе булып эшли, «Ялкын» һәм «Совет мәктәбе» журналлары редакцияләрендә партоешма сәркатибе ярдәмчесе була.

[4] Мәхмүт Хафиз улы Хөсәенов (1923–1993) – язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1993).

2. Сез әдәби процессны оештыру ягыннан бу елларда Татарстан Язучылар берлеге һәм әдәби басмалар тарафыннан башкарылган эшләрдән канәгатьме? Сезнеңчә, XI съезд карарлары тиешле дәрәҗәдә үтәлдеме?

3. Әдәби фондның алдагы эшчәнлеге нинди булырга тиеш?

4. Алда торган съездан сез нәрсәләр көтәсез?

5. Иҗат берлегебез татар әдәбиятын тагын да үстерү өчен нинди мөһим чаралар үткәрергә тиеш дип саныйсыз?

***Җаваплар***

1. Һәр буын әдәбиятының көче яшьләрдә. Өлкән буын вәкилләренең, каләм чарлап эш күрсәткән урталарның көч дәрәҗәсе мәгълүм. Бүгеннәрдә, ягъни тарихның кискен борылыш чорында, алардан әлләни, дөнья җимерерлек яки төзерлек әсәрләр көтеп булмый. Берара офыктан яшьләр югалып торды да менә дүрт-биш елда яшьләрдән берничә кеше калкындылар, буй күрсәттеләр. Әле прозаик Фоат Садриевтан да, философ, тел остасы һәм зур әзерлекле публицист Марсель Галиевтән дә дөньяны биеклектән торып кирәгенчә аңлата алырлык әсәрләр көтеп була. «Идел» журналы тирәсендә тупланган, адымнары ныгып барган яңа буын вәкилләре дә әдәбият офыгында нык ук шәйләнәләр. Драматургларның көчле бер отряды туды. Зөлфәт Хәким, Мансур Гыйләҗев, Гафур Каюмов, Данил Салихов. Татар сәхнәсе байтак еллар дәвамында алар кулында булачак. Театр – татарны милләт итеп саклаучы төп көчләрнең берсе.

2. Әгәр әдип нидән дә булса канәгать икән, ул дөнья бәрелешләре мәйданыннан китәргә тиеш. Фикерләр бар, ләкин алар әлегә берәүгә дә хаҗәт түгел. Берәүләр әдәби казанышларга ирешергә теләп туктаусыз иҗат иткәндә, (мин Гариф Ахунов, Нурихан Фәттах, Мөхәммәт Мәһдиев, Мөсәгыйть Хәбибуллин, Хисам Камал һ.б. чордашларымны күз алдымда тотам!) Җәвад Тәрҗеманов, Ибраһим Нуруллиннар юк дан артыннан каулашканда, язучылар төрле кысан почмакларга таралдылар. Сөйләшкәннәре әдәбият турында гайбәтләрдән узмый. «Әдәби климакс» кичерүчеләр, эш күрсәтү урынына, эшлекле әдипләрне ничек язарга һәм нәрсә язарга өйрәтү

юлына бастылар. Бу өлкәдә кырык ел татар тормышыннан аерылган мәскәүле диңгезче Миргазиян Юныс алда бара. Астыртын кинаяләр, төрледән-төрле шик-шөбһәләр таратып, ул әдипләр арасына ызгышлар гына өсти. Әдипләргә аратирә генә булса да бердәмлек тә кирәк.

3. Барыннан да элек әдәби фондның үзе булырга тиеш. Тарткалый-йолыккалый торгач, «әдәби фонд» ярык тагарак янында калды. Татарстан хөкүмәте әдипләрнең матди тормышын аңлап, литфондның үтә зарури бер оешма икәнен онытмаса, язучыларга яшәү җиңелерәк булыр иде. Язучы икмәге – бүген зур авырлык белән табыла торган әче икмәк.

4. Көтмим. Барыннан да бигрәк «көтмәскә», нәрсәләр «көтмәскә» икәнен алдагы съезд әйтер. «Кияү булсак та» бу «съезд-туй» безнеке түгел инде. Сүзне яшьләр алсын, байрак алар кулында. Алар көтә. Көтәргә хаклары бар.

5. Иҗат берлеге бары тик яшьләр әдәбияты белән генә шөгыльләнергә тиеш. Татарча әз-мәз аңлаучылар бар. Татарча яза алучылар юк дәрәҗәсендә. Өмет мәктәпләрдә, гимназияләрдә. Татар теленең кулланыш дәрәҗәсен төпле кануннар белән ныгытмаганда, аерым кешеләрнең дәрт-дәрманы белән генә халкыбызны үз теленә кайтарып булмаячак. Берлек яшьләр, балалар арасына үтеп керүнең мең төрле юлларын эзләп табар да һәр табышны өзлексез ныгыта барыр, дип уйлыйм.

Бирсен Ходай! АЯЗ.

## «Я испытываю угрызения совести»[1]

*(Интервью Ольги Стрельниковой, 1994)*

Его и в прежние времена нечасто можно было увидеть на писательских собраниях, в почётных президиумах, в списках кандидатов – где бы то ни было... Но вопросов это не вызывало, для парадных речей хватало своих же, парадных «генералов» от литературы. Аяза Гилязова просто читали... Поэтому когда пришло время публичных покаяний, он опять же не суетился, не строчил заказные мемуары, хотя ему бы-

[1] Әлеге мәкалә «Республика Татарстан» газетасының 1994 елгы 17 март санында басыла.

ло что вспомнить и про сталинские лагеря, и про негласные табу... Перемены вызывали у него живой интерес, но он как бы ждал чего-то ещё.

А сегодня во что только не «ударились» бывшие советские писатели – в политику, коммерцию, мессианство. Аяза Гилязова среди них нет...

* * *

*– Аяз Мирсаидович, и всё-таки не очень верится в Вашу полную безучастность. Видимо, есть причины, заставляющие Вас быть сдержанным? Надо полагать, они связаны с обстоятельствами, общими для всех нас и, думаю, если Вы поделитесь своими мыслями, к Вам прислушаются многие.*

– Конечно, причины есть. Изменилась моя жизнь, изменились, к сожалению, некоторые мои взгляды. Скажем, я всегда знал, что рано или поздно империя под названием «Советский Союз» рухнет, и по-своему участвовал в этом. Подтвердились и другие мои прогнозы. Ошибся я лишь в одном – определяя в этом будущем своё место. Вот вы сказали: «Многие к вам прислушаются», а у меня, честно говоря, такой уверенности нет.

Раньше я действительно видел смысл в общении с людьми, своими читателями, знал, что они ждут от меня какой-то ясности, понимания. А сегодня разве писательское слово имеет для кого-то вес? И не только у нас в Татарстане. Возьмите весь бывший союз – и там очень многие писатели умолкли. И среди тех, кто умолк, есть мои идейные друзья, с которыми я не всегда был знаком лично, но разделял общие взгляды.

Меня поражает то, что люди, которые во времена Сталина, Брежнева ничем не гнушались ради того, чтобы поймать на себе милостивый взгляд «сильных мира сего»,– они и сегодня кричат громче всех, опять заглушая голоса умных, совестливых людей. Я бы даже сказал, что раньше у них, совестливых, было больше шансов быть услышанными. Разве с кем-нибудь заигрывали Юрий Казаков или Василий Макарович Шукшин? Да тот же Юрий Черниченко... В начале шестидесятых он опубликовал в «Новом мире» статью «Русс-

кая пшеница». Я тогда учился в Москве и всем писал в Казань: «Читайте... Не пропустите...» Тогда я ему верил. Были такие люди и в литературе, и в театре.

– *Возможно, это же ощущение собственной ненужности, падение авторитета литературы и привели многих известных писателей в политику? А Вы никогда не думали об этом как о своего рода альтернативе писательскому труду?*

– Я никогда не воспринимал и не воспринимаю всякого рода уличные шествия с их дешёвыми популистскими лозунгами. А надо признать, что на современным этапе, во всяком случае, год, три года назад, политика сводилась именно к этому. И как результат: в национальные лидеры выдвинулись люди, которые ничего не смыслят в экономических законах, государственном устройстве. Завоевать популярность им позволило одно – критика коммунистов, дескать, они были и остаются у власти, лишь сменив партийный билет на депутатский значок нового образца. Я много думал об этом... Хотя тоже никогда не любил коммунистов и в своих книгах пытался показать, какую злую шутку сыграли они со своим народом, историей, но... Во-первых, и среди коммунистов были умные, порядочные люди, во-вторых, где и когда новое поколение наших руководителей могло пройти школу управления, школу хозяйствования? А у бывших коммунистов, даже учитывая издержки старой системы, такой опыт есть, и не во всём он бесполезен сегодня.

И прошлые, и нынешние наши несчастья – от всеобщей экономической безграмотности. К примеру, мы, писатели, чем довольствовались? Привезут нас в район, покажут один-два передовых хозяйства, потом секретарь райкома назовёт несколько общих цифр... Кстати, я никогда не мог отличить одного секретаря райкома от другого, насколько одинаковы они были: легко общались, легко прощались... И в нашей литературе, между прочим, они как одно лицо. Так вот, в этих поездках я не помню случая, чтобы кто-нибудь из писателей выразил желание встретиться со специалистами, управляющим банком, наконец, чтобы докопаться до истинного положения дел. И не возникало оно именно потому, что про экономику писатели знали только то, что она должна быть экономной...

Недавно мне попала в руки «Занимательная физика», изданная в Америке. С её помощью я решил восполнить пробел своих знаний в этой области. Дошёл до квантовой механики, её я уже не понимал, а без квантовой механики двигаться дальше уже не мог... То же самое и с экономическими знаниями. Без них наше общение с деловыми людьми, особенно с новым поколением, становится всё более затруднительным, что в конечном итоге и отодвигает нас в свой укромный угол.

Что касается писателей, то большего сожаления, на мой взгляд, заслуживает как раз их излишняя приземлённость, зашоренность «текущим моментом» либо погружённость в те пласты истории, над которыми уже потрудились легенды, и в лучшем случае это порождает ещё одну. Но если человек берёт в руки книгу современного писателя, то, как правило, потому, что ему важно что-то понять о себе самом, о своих отношениях с людьми, Богом... Я не хочу вслух произносить такие слова, как «нравственность», «духовность», но если они потеряют ценность для литературы, то в ней будет лишено смысла и всё остальное...

Вот уже более тридцати лет я пишу... И всегда был склонен думать, что это есть моё служение народу. Но, скажите на милость, разве за эти годы мой народ стал лучше, счастливее? Или, может быть, стала больше его вера в справедливость? Всё-таки каждый писатель несёт ответственность за определённый отрезок времени, который измеряется его собственной жизнью, по меньшей мере. Для меня – это военные, послевоенные годы... Я не скрою, меня мучают угрызения совести. Особенно, когда я смотрю на наше молодое поколение, а вернее, на ту его часть, которая хорошо освоилась в новых условиях и поднялась на поверхность нашей жизни, как пена. Возможно, всё ещё изменится, изменятся и эти молодые люди, которые под видом экономических новшеств уподобили страну зоне, где творится беспредел... Но пока – как отрешиться от того, что они дети нашего поколения? Это наши сыновья. А раз так, то почему мы не узнаём в них себя? А они разве понимают нас, нуждаются в нас? Сегодня самый большой тираж для татарской книги 3–4 тысячи экземпляров. Когда такое было?

Поймите меня правильно, у меня нет ностальгии по коммунистическому режиму. Более того, я считаю, если мы попытаемся дважды войти в эту реку, погибнет всё. Но нет у меня и веры в светлое демократическое завтра. Вот эти центробежные силы и отбрасывают меня всё дальше и дальше от так называемый «гущи жизни». Разобраться бы в этом, что уже содеяно...

— *Но, может быть, это всё-таки временное явление? Наладится жизнь, у людей спадёт камень с души, и для книг появится время?*

— Видите ли, писатель – тоже живой, импульсивный человек. Ему отпущен не такой уж большой срок для того, чтобы убедить себя и других в оправданности своих творческих усилий. И когда приходит время итогов, он не может не спрашивать себя: откуда это недовольство собой, когда и в чём он заблуждался? Именно об этом я сейчас много думаю и не снимаю с себя ответственности за то, что духовно мы свой народ погубили. И только одна мысль даёт мне утешение: там, где есть место покаянию, не угасает и вера.

— *Связано ли с Вашим нынешним состоянием то, что именно сегодня, когда уже столько написано о сталинских лагерях, вы опубликовали свой роман-воспоминание на эту тему?*

— Я исполнил свой долг перед теми людьми, с которыми судьба свела меня в «особом лагере» – как они стали называться с 1948 года. Кстати, именно об этом периоде сталинского режима до сих пор написано не так уж много. В «особом лагере» я провёл с 22 до 28 лет. Надо ли говорить, что это за годы? Это моя молодость, её лучшее время. Сегодня осознавать это даже тяжелее, чем тогда. И если бы не те замечательные люди, которых я там повстречал, моя дальнейшая жизнь могла бы сложиться иначе. Они во многом помогли мне разобраться, а главное – не утратить веру в человеческую доброту. Об ужасах этого времени написано немало, но мне хотелось передать именно ощущение полноты жизни, которое я испытывал рядом с этими людьми. И это был мой долг – помянуть их добрым словом.

Писать было тяжело, я долго не мог найти верную тональность, пока не открыл Коран и не прочитал: «Разве ты не

видел, как Аллах приводит в притчах доброе слово – оно, как дерево доброе: корень его твёрд, а ветви в небесах...» Это была моя молитва. Она помогла мне снять тяжесть с собственной души и утешить души тех, кому я посвятил свои воспоминания.

– *Аяз Мирсаидович, Вы верующий человек?*

– К сожалению, я не могу сказать так, хотя часто открываю Коран, знаком и с Библией. И меня по-настоящему радует, когда я вижу в деревне мечеть или церковь. Уже само по себе это облагораживает землю и людей, живущих на ней, возвращая им заботу о душе, а не только о хлебе насущном. Что бы там ни говорили, народ в деревнях стал жить лучше в смысле быта и его достатка. Он опустошён внутренне. То, к чему всегда тянулась его душа, находилось либо за семью печатьями, либо под спудом уродливого воспитания.

– *Между тем татарские писатели всегда с какой-то затаённой надеждой всматривались в деревенскую жизнь, поэтизировали ее... Или та деревня, о которой они писали, существовала лишь в их воображении?*

– Писатель всегда стремился воссоздать национальный характер. В «чистом» виде его уже нигде не встретишь, но носителем основных и узнаваемых его черт остаётся татарский крестьянин. Этим он и представляет интерес для писателей. Впрочем, сказанное касается и русской, и любой другой национальной литературы. Не мной замечено, что ближе всегда к правде при изображении русского национального характера тоже оказались писатели – «деревенщики». А недавно открыл для себя замечательную прозу Григория Кановича, еврейского писателя...

Думаю, что и впредь татарская литература преимущественно будет «деревенской», потому что именно в сёлах живёт большинство наших читателей. Здесь не существует проблемы родного языка, его действительно впитывают вместе с молоком матери. А потому здесь наши книги читают и ждут. И будь иначе – татарская литература не выжила бы. В городе татарского языка почти не знают, а то, как здесь пытаются привить «любовь» к нему, лично у меня вызывает только

чувство досады. А ведь от этого зависит будущее нашей литературы.

— *Вот давайте о нём и поговорим. Тем более что один из Ваших сыновей, Мансур, пошёл по стопам отца и стал драматургом. Каким видится Вам его будущее?*

— Его будущее меня тревожит и гораздо больше, чем будущее двух других моих сыновей. Ему будет трудно жить уже потому, что любимая работа не сможет его прокормить. Профессия писателя как таковая вырождается. Литфонд пал, гонорары от книг «проедаются» быстрее, чем отпечатывается тираж. Писатель вынужден искать дополнительный заработок, идти на службу. И всё ничего, если бы это не отнимало физические и душевные силы, необходимые писателю совсем для другого. Кроме того, я знаю, что сын «отравлен» драматургией, его пьесы лучше моих, я всё-таки прежде всего прозаик,— и тем неизбежнее для него эта раздвоенность. Наши взгляды на жизнь, творчество не всегда совпадают, но меня это не удручает. Взгляды молодых шире, они образованнее нас и опять же — им труднее, чем нам...

## «Әдипнең кадере бетте...»[1]

*(Рифә Харрасова[2] әңгәмәсе, 16 гыйнвар, 1995)*

— *Аяз абый, тырыш ир-атны мин сезнең кыяфәттәрәк күз алдына китерәм: уртача буйлы, туры карашлы, кайчакта сынаулырак та, йөреше — кызу... Андый кешеләр чагыштырмача намуслы, үз юлларында максатчан, бераз беткелдегрәк тә, гаиләләре турында һәрдаим кайгыртып яшиләрдер кебек. Шул ук вакытта озын буйлылар, бераз һавалы, масаючан — кресло кешесе... Сезгә карата минем бу уйларым ни дәрәҗәдә дөрес?*

— Рифә, Сез миңа бик кыен чакта бирәсез бу сорауны. Мин үземне бик тырыш кеше, гомерем буе эшләдем, берчакта да эшләмичә тора алмадым, дип әйтер идем — ул тырышлыкларның нәтиҗәсе кайда? Нәрсәгә ирешелде? Тормышым

---

[1] Гыйләҗев А. «Әдипнең кадере бетте» / Рифә Харрасова (Рифә Рахман) // Мәгърифәт.— 1995.— № 4(162).— 28 гыйнвар.

[2] Харрасова Рифә Фатхрахман кызы (1962) — филология фәннәре кандидаты (2002), доцент, язучы.

яхшырдымы? Башкалар тормышын үзгәртә алдыммы? Хәзерге вакытта әнә шундый борчулы, буталчык уйлар тозагында, тырыштым һәм максатыма ирештем, дип сөйләү бик тә авыр...

Утыз биш-кырык ел буе әдәбиятка хезмәт итәм. Гомерем буе халыкка ниндидер мәгънәви сүз әйтергә омтылдым. Ирештемме мин аңа? Нәрсәне дә булса уңай якка үзгәрттемме?

Яшь чагында, Каракалпакстанга баргач, бер ишәкне (салган баштан булгандыр инде) кочаклап елаган идем мин. Этләргә затлы нәселдән булган өчен дә медаль тагалар, син гомереӊ буе эшләп тә бер рәхмәт сүзе ишетмисеӊ, дип... Ярым көлеп, ярым елап. Без дә әнә шул ишәк хәлендә. Әдипнеӊ кадере китте. Әдәбиятныӊ дәрәҗәсе бөтенләй онытылды. Дөрес, миӊа да исемнәр дә бирделәр...

Тормыш кинәттән үзгәрде. Үзгәрешләр киләсен мин беләидем. Без үзебез дә тормышны яхшы якка үзгәртергә тырыштык. Әдәби әсәрләр яздык, сәхнәләрдә уйналдылар. Без шул үзгәргән тормышта тибәрелеп читтә калдык. Без көткән тормышмы бу? Илдә яшәвебездән нинди мәгънә калды? Болай сөйләү минем үз капризымныӊ гына чагылышы түгел. Безнеӊ күбебезне шундый уйлар борчый. Узган ел әнә унга якын әдипне югалттык. Быел исә тагын икене җирләргә өлгердек инде. Бу хәлләр яхшы көннән түгел. Элек, әдәбиятныӊ тормышны уӊай якка үзгәртү көче бар, дип ышана, сөйли идек. Инде менә Чечня сугышы безнеӊ күӊелебезгә тагын да зуррак шом салды. Рәсәйдә бер генә акыллы җитәкче дә калмады микәнни, дип уйлыйм мин хәзер. Бүгенге сөйләшүне дә Чечня темасыннан башка күз алдына китерә алмыйм, чөнки бу сугыш безне тетерәндерде, куркытты. Һәм үзгәрешләрнеӊ без көтмәгән якка булуын күрсәтте.

Тырыш кешеләр кирәкме хәзерге заманга? Андыйлар кай якка карап хезмәт итә бүген? Максатлары нинди? Мин беләм, бер генә илдә дә, бер генә җирдә дә оҗмах юк.

Ә бүгенге безнеӊ тормыш — өметсезлектер.

— *Сез — әдәби жанрда каләм мастеры. Әмма тормыш проблемаларын ачып салган, күтәреп чыккан, чишү юлларын күрсәткән публицистик мәкаләләрегезне укыганым юк.*

– Мин бу чорда үземнең урынымны тәгаен генә билгели алмыйм. Шуның өчен дә бик күптәннән интервьюләр биргәнем юк, мәкаләләр дә язып чыкмыйм. Халкыма, укучыларыма, чордашларыма, милләтемә төпле, өметле сүз әйтә алырмын, дип уйламыйм. Әгәр дә әдип әйткән сүзнең көче кими икән, ул тукталып торырга тиеш.

*– Шулай да сез милләт язмышы турында уйланасыз, борчыласыз. Ул уйларыгыз белән һич югы әдәби әсәрләр аша бүлешергә иде. Соңгы арада алары да күренми шикелле?*

– Минем андый теләгем бар. Чыннан да, язучы белән укучы арасындагы күңел арадашлыгы кимеде. Мин гомерем буе милли әсәрләр язарга тырыштым. Иҗатымда бербөтенлеккә ирештем дә, дип уйлыйм. Бәлки, кабатланырмын да: әйткәнемчә, мин халыкның да кая таба барганын, нәрсә теләгәнен аңламыйм, күрмим.

*– Бу, бәлки, профессионал язучы булуыгыз белән дә бәйледер инде, сезне кайдадыр очрату, табу – кыен эш. Төрле митинг, җыелышларда да күренмисез. Әдәбияттан бик үк читтәге кеше булмасам да, сезне әдәби әсәрләрегез аша гына таныйм. Гади укучы бөтенләй аз беләдер, дип уйлыйм. Моның асылында нәрсә ята? Күренмәскә тырышумы? Читтән генә күзәтүче рολендә яшәүме, популярлашудан куркумы, әллә вакытыгыз юкмы?*

– Мөгаен, бу сорау минем үз күңелемә дә еш киләдер. Аңа да бүген өзеп кенә җавап бирергә кыймыйм. Беренчедән, мин хәзерге күп төрле сәяси хәрәкәтләргә бераз шигәеп карыйм. Аларның мәгънәви дәрәҗәләрен дә аңлап бетермимдер. Хәзер, өлкәнәйгәч, бераз кырыслык, сабырлык та инде күңелгә.

– Аннан, соңгы вакытта халык арасында ниндидер бер бүленеш башланды. Берәүләр бик активлашты, берәүләр бөтенләй күренми башладылар. Бу – матбугатта да шулай. Әйтик, Мөхәммәт Мәһдиевнең бер-бер артлы мәкаләләре чыгып тора. Гариф Ахуновны да төрле җыелышларда күрергә мөмкин. Митингларга да йөрүчеләр бар. Ә минем күңелем андый эшләргә инде суынды.

*– Ярар, бу Сезнең бизгән гадәтегез булсын, ди. Кешенең бит әле аерыла алмый торган киеме, шул киеме өстеннән төшмәгән*

*шикелле, янында яшәүче иң яраткан әдәби әсәре була. Авыр уйлардан бер генә минутка читкә китик әле.*

– Бар минем, яратып кигән киемнәрем дә бар. Менә яшәү рәвешем генә түгел, соңгы елларда киемнәрем дә алмашынды кебек. Мин электә дә әлләни фырт булмадым, ләкин әле галстуклар тагып, костюмнар киеп йөргән чакларым бар иде, аяк киеменә дә игътибарлы булдым. Ә менә туксанынчы елдан бирле бер кием дә алганым юк. Беренчедән, моңа минем материаль хәлем дә мөмкинлек бирми. Икенчедән, әйткәнемчә, яшәү рәвешендә дә гадирәк була барам. Гапгади свитер киям. Кигән киемнәрем дә – электән калган киемнәр, алар арасында яратып кигәннәре дә бар. Яшьрәк чакта бөтен нәрсә белән дә шаккатырырга уйлыйсың. Тормыш катлаулана барган саен, без гадирәк була барабыз.

– *Яшьрәк чакта шаккатырырга уйлыйсың, дигәннән, бу әдәби сүзгә дә кагыладыр инде. Менә бу сыйфат бүген әдәбият мәйданына килгән егетләребезгә дә хасмы? Заһид Мәхмүди, Ләбиб Лерон прозасын, әлеге дә баягы «Гасыр романы» белән «Идел» журналында күренгән (жанрын төгәл билгеләргә дә кыендыр инде аның) әсәрне дә күздә тотып әйтәм мин.*

– Рифә, хәзер инде татар әдәбияты үзенең сайлаган тыкырыгыннан гына бара алмый. Яшьләр бер Татарстан белән генә яшәми. Читкә дә чыга алар. Дөнья белән танышалар. Телевизор, видеомагнитофон, радио һ.б.лар хәзерге заман яшьләрен бөтен дөньяда бара торган үзгәрешләргә кыю рәвештә алып керделәр. Артистларны гына алыйк. Аларда да кирәгеннән артык булган гадилек калмады. Заман үзгәртә. Бүгенге көн – эзләнүләр чоры. Хәзерге яшьләр билгеләнгән кысаларга гына сыя алмый инде. Бу әдәбиятта да чагылыш таба. Аның алгы сызыгына чыгып бара торган яшьләр: Нәбирә Гыйматдинова[1], Гафур Каюмов[2], Зөлфәт Хәким[3], Ләбиб

---

[1] Нәбирә Минәхмәт кызы Гыйматдинова (Бикчурова, 1956) – язучы, журналист. Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (1995), М. Җәлил исемендәге Республика (2009), Г. Тукай исемендәге (2013) Дәүләт премияләре лауреаты.

[2] Гафур Шәкүр улы Каюмов (1959–2018) – драматург, театр режиссёры.

[3] Зөлфәт Зөфәр улы Хәкимханов (1960) – язучы.

Лерон[1]нар татар язучылары булып калган хәлдә, аның кануннарын берникадәр җимерәләр, нәрсәнедер үзгәртәләр, алмаштыралар. Бу, билгеле, берникадәр ризасызлык та тудыра. Ә мин моны хаклы үзгәрешләр дип санайм. Дөрес, бу үзгәрешләрнең кая кадәр барып җитәчәген тотып алу кыен. Шулай да, шушы агым булып килгән яшьләр, татар әдәбиятының алымнарын, традицияләрен бөтенләй онытып бетерерләр, дип уйламыйм. Заман, күргәнегезчә, кискен үзгәрә, күз иярмәс дәрәҗәдә алмашына. Бу алмашыну, үзгәрешләрне җете күзле яшьләр беренче нәүбәттә тотып алырга тиеш. Татар әдәбияты гел үзгәрешләр юлы белән генә барсын, дип әйтергә җөрьәт итмәсәм дә, яшьләр киткән юл минем өчен кызыклы.

Әлбәттә, татар әдәбиятына, прозасына кыюлык, белем, дөнья күрү җитми. Бу сыйфатлар безнең буынга да хас булды. Ләкин безнең буынның язу хокуклары чикләнгән, махсус даирәләр тарафыннан кысылган иде. Хәзерге рухи иркенлек чорында яшь алмаштан фәлсәфи тирәнлек, гуманитар активлык, мәгънәви бөеклек көтәм.

— *Тормышта гадиләшә төштем, дидегез. Бу — сезнең әдәби әсәрләрегездә дә чагыламы, яисә чагылырмы? Менә без Сибгат Хәким, Хәсән Туфаннар иҗаты турында сөйләшкәндә, алар иҗат юлларының ахырында гадиләшә төштеләр, халыкка якынайдылар, традицион калыпларда иҗат иттеләр, дигән сүзләрне еш ишетәбез.*

— Минем әле «Йәгез, бер дога!» романыннан соң әсәр язып караганым юк. 94 нче ел — бик авыр ел булды. Чир-чәнке якага үрелде. Мин язарга тиешле әсәрләр — күңелем хөр, рух иркен чагында уйланылган әсәрләр. Кул кычыта. Татар прозасының бүгенге бертөрлелеген җимереп, кыю, тирән бер роман язасым килә. Мин аңа бик күптәннән әзерләнәм. Бисмилланы әйтеп, эшкә дә тотынырга иде, ләкин бүгенге

---

[1] Лемон Лерон улы Леронов (1961) — язучы, шагыйрь, журналист. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2002), Татарстан Язучылар берлегенең Ш. Маннур исемендәге (1994) һәм А. Алиш исемендәге (2000) премияләре, М. Җәлил (2007), Г. Тукай (2022) исемендәге Республика премияләре лауреаты.

җәмгыятьтә әдип сүзенең кадере кимүе итәк-чабудан тотып тора.

Аннары яшермик: әдәбият хәзерге көндә тамак ялгарлык та акча китерми. Инде күптән ялда булырга тиешле пенсионер язучыларыбыз юк кына хезмәт хакына кайдадыр эшләр эшләп йөриләр икән, бу инде – аяныч хәл. Алар бит гомер буе тырышып эшләгәннәр, әдәбиятыбызны үстерүгә зур көч куйган әдип һәм шагыйрьләр.

*– Сезнең «Балта кем кулында?» әсәре хакында укучыларым белән еш кына бәхәскә кергәлим. Кайберләренең, язучы үзе куйган сорауга җавап бирми, әсәрнең чишелеше юк, дияселәре килә. Имеш, ачы язмыш аркасында төп герой бәрелеп-сугылып йөреп, төрле михнәтләр чигә, үзен таба алмый. Фәрваз Миңнуллин әнә: «Балта явызлар кулында?» дип язып чыкты. Мин исә, Аяз абый, явызлыклар без яшәгән системаның нигезенә салынган, шул системада билгеле бер пост, эш урыны биләүчеләр тоткан ул балтаны, дип язган, дим.*

– Мин бу романда әйтәсе килгән җавапны үземчә әйттем. Аны аңлау һәм кабул итү, әлбәттә, һәр кешедә үзгә булырга мөмкин. Әйтергә теләгәнем шул: социалистик яшәү рәвеше кешеләрне кая илтеп җиткерә?! Билгеле, бу – система. «Балта кем кулында?» романы – минем иң чын күңелдән язган әсәрем. Ул – нindидер дәрәҗәдә йомгаклау сүзе дә.

*– Сез – гомер буе безнең системаны тәнкыйтьләп язган кеше. Шулай да, аның җитешсезлекләрен ни дәрәҗәдә ачканыгызны әдәби тәнкыйть тулаем тотып алмаган кебек. Шуңадырмы, әсәрләрегез дә басыла торган...*

– Әйе, минем әсәрләремнең бөтенесен бергә күз алдында тотып әйткән кеше юктыр, дип уйлыйм. Моңа кадәрге әдәби тәнкыйть тә анда әйтелгән фикерләрне тотып бетерә алмады. Бәлкем, аларның басыла килүе шуңа да бәйледер.

Мәрхүм Фәрваз Миңнуллин соңгы мәкаләсендә мине аңларга тырышкан. Иҗатым турында мин көткәнчә ул гына нидер әйтә алган, дип кабул иттем.

*– Аяз абый, менә сез безне «гадел булыгыз, гадел яшәгез, кешеләргә авырлык китермәгез» дип өйрәтәсез. Гадел яшәп бәхетле булып буламы? Балаларыңа кирәк дәрәҗәдә белем биреп, яшәү шартлары тудырып буламы? Әгәр булмый икән, сез безне*

*дөрес яшәргә өйрәтмисез булып чыга ич. Нишләргә? Явызлык, гаделсезлек дөньясында мескен булып яшәргәме? Әдәбият бездә яшәү идеалы тудыра, якты киләчәкне күрсәтә, дип сөйләдек. Бу – буш сүзләр булып чыктымыни?*

– Сез бик кызыклы фикерләр әйтәсез әле, Рифә. Минем менә алдагы романда, язылачак романда бу турыда сүз булачак. Кешеләрне гадел булырга тәрбияләп, без аларны кайвакыт харап итәбез дә, чөнки абсолют гаделлек бер җирдә дә юк. Кешеләр усаллар белән усалларча сөйләшергә әзер булырга тиешләр. Менә мин үз балаларымны да тыйнак, сабыр булыгыз, бер-берегезне рәнҗетмәгез, хезмәттә үз көчегез белән генә көн күрегез, дип тәрбияләдем. Хәзер инде уйлап куям: дөрес эшләдемме?

– *Мин, үзегез әйткәнчә үк, әдәби әсәрләр бүгенге көндә язмыйсыздыр, дип уйлый идем. Сез менә безнең җәмгыятьне тәнкыйтьләдегез, тәнкыйтьләдегез... Тәнкыйтьләп, үзегез көтмәгән үзгәрешләргә үк алып килдегез түгелме? Инде хәзер менә – ләм-мим. Мин инде, Аяз абый үзгәрешләр чорын тәнкыйтьләргә дә курка, прогноз ясап, ялгышудан да шүрләп куйды, ахры, дигән фикергә килгән идем. Бәлки, әдәбиятта соңгы сүзне ялгыш әйтергә теләмисездер?*

– Әйе, әйткәнемчә, мин империянең таралачын да белдем, ниндидер дәрәҗәдә аның таркалуына да ярдәм итәргә тырыштым, ләкин мин хыялланган үзгәрешләр булмады... Шул үзгәрешләрне теләп язган китапларым кемгә кирәк бүген?

– *Алайса безгә нишләргә инде? Тәнкыйтьләп ялгыштыкмени?*

– Мин бүген ике юл чатында торам. Нишләргә кирәклеген өзеп кенә әйтә алсам, мин мәкаләләр дә язган булыр идем. Инде мин үзем элегрәк өндәгән сүзләргә дә чак кына шигәебрәк карыйм.

– *Газета укучылар – бик кызыксынучан халык бит инде ул. Бигрәк тә аларны танылган артист, язучыларның шәхси тормышы кызыксындыра. Беренче сорау: Сез кызларга ни дәрәҗәдә «битараф»? Һәм кайбер иҗат кешеләренең мәхәббәттә тезгенсезлеге иҗатта ярдәм итә, дигән фикерне хуплыйсызмы? Шул ук вакытта әдәби әсәрләрдәге иң югары әхлакны, бердәнбер мәхәббәтләрне, гаиләдәге идеаль мөнәсәбәтләрне тасвирлаган,*

*пропагандалаган язучылар тормышта нәкъ киресе булып чыгуына нисбәттән нинди фикер әйтә аласыз? Кешеләр итәкләрен җыеп йөрсеннәр, ә мин рәхәтләнеп типтерим, дигәнне аңламамы бу?*

– Мин хатын-кызларга, гомумән алганда да, һичбер вакытта да битараф булганым юк. Безнең татар язучыларының әдәби әсәрләрендә дә булсын, истәлек яисә хатларында булсын, автобиографик әсәрләрендә дә чынлап торып ачылып беткәннәре юк.

Мин үзем элек бик күп кешеләргә хатлар яза идем. Аларны җыйнап, тәртипкә салып бардым. Тормышымның бөтен ваклыклары, әдәби әсәрләргә сыймаган кайбер фикерләрем, әдәби хәрәкәткә булган мөнәсәбәтем, канәгатьләнү яки ризасызлыгым әнә шул хатларда урын тапты. Бәлки, кемгәдер, кайчандыр бу хатларның да файдасы тияр, дип уйлыйм. Кеше үз тормышын язган әсәрләрендә дә ачып бетерә алмый. Бик кызык нәрсә бу. Әнә Мөхәммәт Мәһдиев барлык язганнарыннан үзе күренеп тора. Әмма ачылып беткәнме ул? Гариф Ахунов, киресенчә, аралашкан кешеләрен генә тасвирлый.

– *Бу – язучының хәйләкәрлегеннән дә килмиме? Әйтик, мин мисалга сүз уңаеннан гына алам, билгеле, Гариф Ахунов үзе турында мәгълүматны яшерергә тели, ә Мөхәммәт абый фундаменталь образын тудырып калдырырга тырыша? Үзе турында мәгълүмат бирүе белән дә укучыны җәлеп итә, янына туплый, бәйләнешкә керә?*

– Бәлки, бәлки... Шул ук вакытта мин аларның икесенең иҗатын да яратып кабул итәм.

– *Мөхәммәт абый дигәннән, аның иҗаты хакында «яшьлекне сагыну» гыйбарәсен кулланабыз. Бу, чыннан да, шулай. Сезнең иҗатыгыз аныкыннан күп кенә яклары белән аерылса да, шактый охшаш та. Әйтик, шул ук «үткәнне сагыну» сүзләрен сезнең иҗатка карата да кулланып булыр иде, әмма алай дип язучылар очрамый. Ниндидер бер вакыйгаларга бәйле үткәнгә кайтып төшү алымы да бар... Әмирхан Еники белән охшашлык та сиземләнә.*

– Мин үзем, егерменче гасырның икенче яртысында Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев һәм мин янәшә ба-

рабыз, дип саныйм. Безнең язу стильләребез аерым булсын, фикерләребезнең төрлелеге күренсә дә, без – бер агым кешеләре. Бәлкем, Әмирхан ага белән Мөхәммәт алай дип санамыйлардыр да, әмма мин гомерем буе шулай санап килдем һәм саныйм. Бу ике әдипнең иҗаты миңа һәрвакыт якын булды.

Беренчедән, алар икесе дә – милли язучылар. Мин үземне дә татарның милли язучысы дип саныйм. Татарны яраттым, чиксез яраттым. Әгәр бу хис, милләтне ярату хисе әдипне ташламый икән, ул аның иҗатында гүзәл нәтиҗәләргә китерә. Мин Мөхәммәтне татар совет әдәбиятында төп фигуралардан саныйм. Моның белән бер язучыны да кимсетергә җыенмыйм. Һәркемнең кирәге, үз урыны, үз укучысы бар. Мәсәлән, Гариф Ахуновның укучысы минем укучыларыма караганда күбрәк. Мөхәммәт Мәһдиевнеке дә күбрәк булырга мөмкин. Бер нәрсәне онытмыйк: талантлы язучының талантлы укучылары булырга тиеш. Укучыга карата тәнкыйть сүзе әйтү кыенрак та. Әмма безнең талантлы укучылар саны аз булуын әйтергә кирәк. Бу безнең иҗат үсешебезне дә тоткарлый. Әле баягыча әйтсәк, халыкка ансат барып җитә торган, гадирәк әсәрләр язуга китерә. Андый әсәрләрне укучы укый, укыганда көлә, ябып куя да оныта. Баш ватып тормый. Әдәбиятның төп максаты – ул уйландыру. Кеше дөнья турында да, үзе турында да уйланырга мәҗбүр булырга тиеш.

Әдәбиятның максаты әнә шундый – бик югары! Ул максатка ирешә алдыммы мин үз әсәрләрем белән, аны инде укучылар үзләре бәяләсеннәр.

## Здесь живёт писатель[1]

*(Интервью Галины Зайнуллиной[2], 1999)*

Выдающийся татарский писатель Аяз Мирсаидович Гилязов родился 17 января 1928 года в деревне Чукмарлы Сармановского района. После окончания школы два года работал

---

[1] Әлеге мәкалә «Казанские ведомости» газетасының 1999 елгы 31 декабрь санында басыла.

[2] Галина Инис кызы Зайнуллина – сәнгать фәннәре кандидаты (2010), язучы, тәнкыйтьче.

в комсомольской организации г. Заинска. В 1948 году поступил на татарское отделение историко-филологического факультета КГУ. На втором курсе был арестован и осуждён по двум статьям: 58–10 – «попытка создания антисоветской организации», 58–11 – «клевета на вождя народов СССР». Шесть лет провёл в лагерях Караганды. В феврале 1956 года восстановился в университете, начал сотрудничать с журналом «Чаян». В марте 1961 года был принят в Союз писателей. Профессионалом считает себя после учёбы на Высших литературных курсах в Москве с 1961 по 1963 год.

Автор 40 пьес, множества повестей и романов: «В чьих руках топор», «Август 1918-го» (совместно с Литвиным), «Весенние караваны», «Девичьи письма», «Петух на изгороди» и др. Многие произведения переведены на русский язык.

* * *

С Аязом Мирсаидовичем мы познакомились в середине 70-х годов.

Надо представить себе то десятилетие. Оно было последним для западных писателей, когда тиражи их книг оставались сравнительно большими и издатели ещё не умоляли их писать плохо, чтобы книга принесла деньги. Но никакого сравнения с интересом к печатному слову, царившим в то время у нас, «цивилизованные» страны не выдержали бы. В каждом городе имелось литобъединение, да не одно, юноши делом чести считали не бизнес, а сочинение стихов, на шкале общественных ценностей писатель стоял куда выше, чем директор завода или секретарь горкома КПСС.

Трепет, с которым я переступала порог просторной «сталинки» на Восстания, молодое поколение сегодня вряд ли поймёт: здесь живёт ПИСАТЕЛЬ! Хотя в молодости я целиком разделяла высказывание международного бродяги Эдуарда Лимонова[1], всю жизнь принципиально не обзаводившегося жильём: «Писатель – это тот, кто жрёт сырое мясо. Кто живёт приключениями своего народа. А не тот, кто сидит в Переделкино[2] в кресле-качалке и пьёт кефир». Аяз Мирса-

---

[1] Эдуард Вениаминович Лимонов (Савенко, 1943–2020) – рус язучысы, публицист.

идович противоречил всем пунктам лимоновского определения. Он вёл размеренную жизнь в благоустроенной квартире. Любящая добропорядочная жена Накия растила ему трёх сыновей. А свою прозу Гилязов как раз предпочитал писать в Переделкино.

Именно там, в 90-х годах, он завершил работу над своим последним автобиографическим романом «Давайте помолимся!», который доконал его. Инсульт стал результатом мысленного возврата в сталинские лагеря 50-х годов. Сейчас писатель с трудом передвигается, из дома практически не выходит, спутница жизни Накия читает ему вслух всё необходимое.

Радикальные перемены претерпело и общественное сознание. За 25 лет нашего фрагментарного, но не поверхностного знакомства по числу низколобых молодых людей страна давно догнала и перегнала Америку. Многочисленные лотки с печатной продукцией на улицах Казани по яркости и пестроте схожи с мусорными контейнерами: «Месть Бешеного»[1], «Золото Меченого»[2], «Схватка Бритого»[3].

Но трепет, с которым я переступаю порог писательской квартиры, прежний. И не потому, что я осталась анахронически советским человеком. Дело в повести «В пятницу, вечером...»[4], которая несколько лет лежит в изголовье моей кровати. Я читаю её в подлиннике с татарско-русским словарём каждый вечер вместо очистительной молитвы. Лишь к сорока годам пришло ясное осознание того, с кем мне выпала удача общаться.

Слава богу, глаза Аяза Мирсаидовича всё так же живо и остро блестят из-за очков. Так же часто он смеётся. Как верно заметил когда-то Рустем Кутуй, невпопад, будто на всякий случай. Всё так же непоколебимо жизнелюбив:

– Я счастлив, что отсидел 6 лет и видел то, что никто уже не увидит!

---

[1] В. Доценко китабы.

[2] В. Доценко китабы.

[3] В. Доценко китабы.

[4] Повесть А. Гилязова (1972–1979).

Писатель, кажется, и тому рад, что его тело, материальная оболочка, вышло из строя. Теперь у него имеется уникальная возможность жить и работать душой. Душа же эта скорбит о судьбе татарской литературы, которой отдано 40 лет:

– Я всегда знал, что империя рухнет, всегда. Но не предполагал, что под её обломками исчезнет мой читатель.

– Долго продлится эта ситуация? – спрашиваю я. – Будут ли литераторы востребованы в XXI веке?

– До 2040 года родятся ещё два поколения, писатели будут не нужны, – предрекает Аяз Мирсаидович. – Если всё так будет продолжаться, русские в XXI веке исчезнут, они исчерпали свои силы. Дело в том, что страдает, калечится генофонд нации.

– А татары?

– В век тотального телеоболванивания татары рискуют сначала раствориться в русской стихии, а затем исчезнут вместе с русскими, – ставит он жёсткий диагноз. Не совершает духовного подлога и не пророчит материального изобилия суверенному Татарстану в грядущую эру Водолея.

Так консервативные мусульманские богословы в конце XIX века предупреждали о безблагодатном, растянутом на столетия конце существования человечества. Но 1917 год был воспринят как начало Новой эры очень и очень многими.

– Скрывающий свою болезнь умирает, – продолжаю допытываться я. – Есть такая татарская пословица. Основной изъян народа, который помешает татарам сохраниться в качестве субъекта истории в XXI веке? Назовите его.

– Мелкость души, – выносит приговор писатель. – Её хорошо показал Амирхан Еники в повести «Марево».

Аяз Мирсаидович и раньше призывал меня учиться у Еники, ничего не говоря о значительности своего вклада в литературу.

– Аяз Мирсаидович, в своей повести «В пятницу, вечером...» Вы со знанием дела описываете блуждание астрального тела главной героини Бибинур в тонком мире... – я жду от писателя расхожих откровений о лично пережитом мистическом опыте.

Но он рассказывает мне о чуде высшего порядка – о том, как создавалась повесть:

– Из окна дома в Переделкино было видно три берёзы. Я постоянно смотрел на них и писал. Правда, перед этим я 20 лет носил свою героиню в сердце. Как Флобер[1] восклицал: «Мадам Бовари[2] – это я!», так и я на встречах с читателями говорю: «Бибинур – это я!»

## «Я никогда свободно не дышал»[3]

*(Интервью Резиды Даутовой[4], 2001)*

Так считает известный татарский писатель Аяз Гилязов, размышляя о настоящем и будущем татарской нации.

Судьба Аяза Гилязова могла бы стать учебным пособием по истории татарского народа. Деревенский мальчишка, до 18 лет не знавший ни одного слова по-русски, становится студентом и со второго курса попадает за решётку. Шесть лет ГУЛАГа делают то, чего не смог бы сотворить ни один самый престижный вуз мира. Так считает один из старейших и плодовитых писателей Татарстана Аяз Гилязов.

* * *

– Я думаю, XX век – золотое время для татарского народа. Татары, конечно, многое пережили, однако сколько с этим приобрели! Я не националист, но когда стали закрывать татарские школы и люди стеснялись разговаривать на своём родном языке, мне было очень больно. Но посмотрите: сегодня эти времена уже в прошлом. И вот мы говорим: у нас тысячелетняя литература. Но знали ли мы конкретные имена, произведения тех, кто начинал её? Нет, XX век дал

---

[1] Гюстав Флобер (1821–1880) – «Төгәл сүз» теориясен тәкъдим иткән һәм үз әсәрләренең стиле өстендә туктаусыз эшләгән француз язучысы.

[2] Г. Флобернның «Мадам Бовари» романы героинясы.

[3] Әлеге мәкалә «Восточный экспресс» газетасының 2001 елгы 6–12 апрель саннарында басыла.

[4] Резида Вәгыйз кызы Даутова – тарих фәннәре докторы (2012), доцент (2010), журналист.

нам конкретность истории, ясность осмысления своего пути и возможность мечтать о будущем нации.

— *Но этот же XX век принёс множество испытаний и несчастий. И кому, как не вам — прошедшему тюрьму, лагеря, унижения — не знать об этом...*

— История — не ложка манной каши. Лично я считаю, что годы заключения — трудные, но самые счастливые. Я был свидетелем и участником того, что уже никогда не повторится...

— *Свой последний роман «Давайте помолимся!» Вы посвятили как раз этому периоду. Зная Ваше прошлое, эту книгу ждали давно. Чем объяснить то, что Вы решились написать об этом только сейчас?*

— Считал, что внутренне не готов. А когда начал писать, вдруг понял: кажется, опоздал. Но сегодня радуюсь, что, пока память была свежа, я всё-таки написал этот роман. Во-первых, думаю, ни один писатель в России эту тему так глубоко не разрабатывал. Никто не писал о лагерях, в которых находился я. Они же все были разными. В 1948 году советское правительство почти вплотную подошло к решению начать третью мировую войну. И для того, чтобы «очистить» свой тыл, власти начали собирать в лагеря неблагонадёжных — бывших военнопленных и тех, кого в 37-м уже арестовывали. Такой лагерь, в частности, создали и в Казахстане. Надо сказать, татар там было, по сравнению с другими национальностями, не так много и это были, в основном, солдаты Восточного легиона. 75 процентов всех заключённых составляли бандеровцы. А ещё писатели, профессора, генералы. Много евреев. Все мы были без имени, только — номер.

— *А как попали туда Вы?*

— Да как многие другие — «за попытку создать антисоветскую организацию, за клевету на вождя народов». Хотя я всегда был противником советской власти, но, честно скажу, в то время не казался себе героем. В лагере я встретил своих единомышленников, и это стало для меня большим счастьем. Шесть лет заключения помогли мне многое понять. Тюрьма и лагерь, по сути, не исправили меня, а мои убеждения лишь укрепились.

– *Но анкетные данные были навсегда испорчены.*

– Не то слово! Шесть лет никуда не мог устроиться на работу. Меня забрали со второго курса филологического факультета университета, и я решил восстановиться. Сначала ректор очень хорошо принял меня, а на следующий день... просто не захотел узнавать. Я тогда пошёл в КГБ: хочу, мол, снова учиться в университете, скажите прямо – может, вы против этого. Нет, говорят, не против. В общем, с большим трудом я всё-таки стал снова студентом. А здесь мне опять тычут Ленина... В общем, я окончил только три курса и диплома не получил. Вступил в Союз писателей, поехал в Москву. Всем, чего я достиг, обязан только Литературным курсам. Это был период оттепели – благодатное время, прекрасные учителя.

– *И всё-таки Вам, думаю, всё время приходилось лавировать между тем, что можно было писать и о чём нельзя. Тем не менее вы создали очень много и за вами закрепилась репутация весьма плодовитого писателя.*

– Да, я написал немало. В том числе и 40 пьес. Пьесы кормили лучше, чем проза. Но драматургом себя не считаю. В Москве меня очень ценили, переводили... Но, вы правы, до конца раскрыть свою душу я не мог. Отдушиной были письма, в которых размышлял, философствовал. Например, я однажды уехал в Переделкино на 30 дней, за месяц напечатал на машинке 50 писем жене. Копии сохранились. Сейчас я уже, к сожалению, писать не могу. Глаза не видят. А в лучшие времена вставал в шесть часов утра, умывался – и сразу за работу. Напишу пять страниц, а в 10 часов переписывал их набело. Писатель должен любить сам процесс. Я очень любил. Никогда не уставал. Точнее, уставал только тогда, когда работа не шла.

– *Как известно, Вас не жаловали критики. Это очень трудно – продолжать писать в условиях бесконечной публичной травли?*

– У меня есть папка. Называется: «Пища – я. Критики, которые накормились мной». Я думаю, критиковать меня для них было определённым удовольствием. Да и обком всячески поддерживал это в течение двадцати лет. Думаю, даже

участвовал в организации отрицательных откликов в прессе. Первая моя пьеса называлась «Медный колокольчик». Так вот, газетная редакция получила тогда 35 отрицательных отзывов. Можете представить? Кто только не ругал Аяза Гилязова?! И доярка, и ткачиха, и строитель... Критика, конечно, ранит, но когда начинаешь новую работу – чувствуешь, что ты сильнее всего этого.

– *Когда же Вы, наконец, легко вздохнули?*

– Я никогда свободно не дышал. Душа же живая, отзывается на всё. Сейчас вот волнует крутой поворот судьбы татарского языка, татарской культуры. Конечно, для нас, писателей, сегодня нет запретных тем. Но в современной морали татар настолько всё перепуталось – ценности старшего поколения, устремления молодых, исконно национальные традиции и желание во что бы то ни стало не отстать от мира... Мы сейчас находимся перед таким поворотом судьбы, что даже страшно становится. Конечно, если Россией будет управлять умный человек, мы сохраним многоцветье наций. Но боюсь, вряд ли скоро появится такой. Пока же Россия не хочет усиления татар. А Татарстан – не Чечня, мы не будем воевать за свою независимость... В глубине души мне очень хочется верить, что мы выдержим и это испытание. Но течение истории, увы, не в нашу пользу.

– *Есть мнение, что татарская культура была бы намного богаче, если бы сталинский период не отнял у неё цвет нации.*

– Трудно судить об этом. Кое-кто возможно, был бы более плодотворным и счастливым. Но убеждён: тюрьма делает людей. Да, это тяжёлая судьба. Взять хотя бы Мусу Джалиля. Его жизнь окрашена подвигом. Но мы ещё до конца не знаем, кто такой Джалиль, потому что архивы КГБ до сих пор полностью не рассекречены. Я как-то писал об этом, правда, не всем понравилось. Меня же многие в республике не любят...

– *Кстати, наверное, не без Вашего влияния Искандер Гилязов*[1]*, один из ваших сыновей, заинтересовался историей создания Восточных легионов.*

[1] Искәндәр Аяз улы Гыйләҗев (1958) – тарих фәннәре докторы (2000), профессор (2000), ТР Фәннәр академиясе хакыйкый әгъ-

— Нет-нет, в судьбы сыновей я не вмешиваюсь. Они сами по себе – и Мансур[1], выбравший литературную стезю, и Искандер, нашедший себя в науке. Искандер в молодости всё время говорил: буду путешественником. Я никогда не думал, что он поедет в Германию и посвятит два года изучению этой темы. Его работой я горжусь.

*— Как Вы считаете, писательское слово сегодня в России имеет ту силу, какую имело во времена Герцена[2] и Белинского?*[3]

— Боюсь, что нет. Как это ни горько, я вообще в Россию уже не верю. Я очень любил творчество Солженицына, пока он не увлёкся политикой. Когда же он рассуждает, как обустроить Россию, то выглядит фантазёром. И всё-таки я считаю, что в российской истории XX век запомнится двумя людьми – Андреем Сахаровым[4] и Солженицыным...

*— Вы, наверняка, следите за состоянием татарской литературы. Говорят, что лучшие времена для неё остались позади.*

— Это самый тяжёлый для меня вопрос – кто придёт за нами. До последнего времени я тоже пессимистически оценивал перспективы. Пришли совершенно чуждые творчеству люди, которые занимаются не литературой, а только поддерживают друг друга. В результате читать нечего. Но, слава богу, в последние годы появились значительные произведения, например, таких писателей, как Флюс Латыфи и Галимжан Гильманов[5].

*— Аяз Мирсаидович, каких людей вы включили бы в десятку выдающихся татар XX века?*

---

засы. Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендә дәүләт премиясе лауреаты (2016).

[1] Мансур Аяз улы Гыйләҗев (1961) – язучы, драматург, сценарийлар авторы, күчемсез милек эшмәкәре. ТР атказанган сәнгать эшлеклесе (2006).

[2] Александр Иванович Герцен (1812–1870) – рус язучысы, публицист.

[3] Виссарион Григорьевич Белинский (1811–1848) – рус әдәбият тәнкыйтьчесе.

[4] Андрей Дмитриевич Сахаров (1921–1989) – совет физик-теоретигы, СССР Фәннәр академиясе академигы, диссидент. Нобель премиясе лауреаты (1975).

[5] Галимҗан Хәмитҗан улы Гыйльманов (1957) – татар язучысы.

– Конечно, Тукая, Фатиха Амирхана, которого нынче почему-то пытаются не замечать. Несомненно, и отец нашего театра – драматург Галиасгар Камал. Очень высоко ценю Амирхана Еники и Мухаммада Магдеева. Трудно представить нашу культуру без Гаяза Исхаки, Салиха Сайдашева, Рустема Яхина, Халила Абжалилова, Ильхам Шакиров, конечно,– гений. А последний, десятый пунктик... оставлю для себя. И скажу вам истину – такого прозаика в татарской литературе больше нет...

## Гомер көзеннән әңгәмә[6]

*(Рәмис Аймәт әңгәмәсе, 2001)*

– *Син, Рәмис[7] парин, миннән әңгәмә алырга соңаргансың. Мин инде хәзер элеккеге Аяз түгел...*

Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев белән әңгәмәбез, нишләптер, әнә шундый, минем өчен көтелмәгәнрәк нотада башланып китте.

Тәңре әмередер: адәм баласының язлары, җәйләре, кышлары булган кебек, көннәрдән бер көнне, берән-сәрән өзелеп төшкән сары яфраклар кебек ашыкмый-кабаланмый, моңсу гына гомер көзләре дә якынлаша. Тукай язганча, килә бер көн, күз карашында әшьялар төсе дә үзгәрә…

Аяз ага белән аның фатирында сөйләшеп утырабыз. Ул йомшак кәнәфигә сөялеп утырган да, телевизор белән идарә итү пультының төймәләренә салмак кына, ипләп кенә баскалап, гомер сәхифәләрен алыштыргандай, телевидение каналларын күчерә.

Гомер буе тормыш сынаулары каршында бил бирмәгән, бөгелмәгән, сыгылмаган, нинди генә чорда яшәсә дә, үз сүзен ярып әйтергә курыкмаган Аяз Гыйләҗев бүген татлы да, моңсу да, газаплы да уйлар кочагында. Аксакалны дөнья гаме биләп

---

[6] Әлеге мәкалә «Татарстан» журналының 2001 елгы 9 нчы санында басыла. Ул «Гомернең иң авыр елларын да сагынам...» дип атала (48–53 б.).

[7] Рәмис Кыям улы Аймәтов (1968) – Һ. Такташ (2012) һәм М. Җәлил (2017) исемендәге әдәби премияләр лауреаты, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2019).

алган. Тарихның ил өстеннән дәһшәтле өермә булып узган җил-ле-давыллы гарасатлары да, татарның үткән һәм киләчәктәге язмышы хакындагы тетрәндергеч уйлар да – барысы да, тәкъ-дир тактасы күк, йөзендәге җыерчыкларга язылган. Күз кара-шында әшьялар төсе үзгәрсә дә, йөрәктә еллар салып калдыр-ган сагыш төсе үзгәрәмени соң ул?!

**Хәсрәтне беләме балачак?**

*– Аяз ага, әйдәгез, әңгәмәбезне ерактан – серле сукмакларда уралып калган балачактан башлыйк әле. Сез, нишләптер, әсәр-ләрегездә гомерегезнең әлеге нарасый да, бәхетле дә булган миз-гелләре хакында аз язасыз. Бөтенләй юк, дисәм дә ялгышмам...*

– Балачак, дисәм, хәтеремә бер кызык вакыйга килеп төшә. Җәйләрнең берсендә әнием ындыр түрендәге кыяр түтәлләре арасына барып кергән. Мин, терсәкләремә тая-нып, артымны туңкайтып, борын очым белән җир сөреп, чәнти бармак кадәрле үскән кыяр малаен кимереп ятам икән... Әни, соң дәрәҗәдә гаҗәпләнеп: «Улым, кыярны нишләп ятып ашыйсың?» – дип сораган. Мин, аллы-күкле янып: «Үзең өзмәскә куштың ич»,– дип җавап биргәнмен, имеш... Җавабымны үзем хәтерләмимим, әни сөйләвеннән исемдә калган, ул ышанып сөйләгәч, шул вакыйга балача-гымның иң истәге хатирәсе булып күңелемдә саклана.

Тәңремә рәхмәтлемен: ул мине туганда ук шигъри күңелле иткән, шулай уйлыйм. Хәтергә нык сеңеп калган вакыйгалар шуны сөйли.

Минем әтием – тумышы белән Сарман кешесе. Үз-үзем-не белә башлаганда, без Югары Баграж дигән гүзәл керәшен авылында, нәкъ чиркәү каршысындагы пуҗымда, Әндриян дәдәйләр өендә яши идек. Әндриян дәдәй – балта остасы, аны Федоттагы ятим балалар йортына эшкә чакырып алган-нар да, ул гаиләсе белән шунда яшәп ятканда, без алар өендә тордык. Минем татлы, кадерле балачак истәлекләрем Җир шарының шушы нәни ноктасы белән бәйләнгән.

Әти урта мәктәптә химия, биология укыта, кич-иртә бак-чада казынырга нык ярата иде.

Соңгы сигез гасыр эчендә дөньяда табигатьнең иң мәрхәмәтле еллары утызынчы белән кырыгынчы еллар арасына туры килә.

Җир сирәк тетрәгән, зилзиләләр сирәгәйгән, янар таулар яман утларын сак чәчкәннәр, җәйләр җылы, мәрхәмәтле, шәфкатьле булган. Утызынчы–кырыгынчы – минем бәхетле балачагым еллары! Мин хәзерге әле коры, әле яңгырга тоташ манчылган җәйләрне ул бәрәкәтле еллар белән чагыштырып карыйм, һәм хәзерге заман балаларын уйлап күңелем сызлый... Җир мәрхәмәтле, сөйкемле еллар белән дә безне иркәләгән икән!

Әнием Мөгаттәрә дә – Сарман төбәге кызы, Сарманга терәлеп үк торган Югары Әхмәт авылында туып үскән. Әти Минзәләдә педучилищеда укый башлагач, әнием шунда ук кызлар мәктәбендә белем алган. Минзәләдә танышканнар алар, шунда кавышканнар. Әтине эшкә Чукмарлы авылына җибәрәләр, әни, бер-бер артлы өч малай табып, өйдә утыра. Әтине, яшь мөгаллим дип, район читендәге Югары Баграж авылына укытырга күчерәләр. Авыл Зәй районы карамагына күчкәч тә, безнең гаилә Багражда калган. Минем балачагым, яшьлегем әнә шул авылда, юмарт күңелле, кунакчыл, гади, үтә кешелекле, риясыз-хәйләсез керәшеннәр арасында үтте. Олысы-кечесе безне хөрмәт итә иде. Көрәк сакаллы, абруйлы авыл агайлары әниемне яратып, гади укытучы хатынын зурлап, «апа» дип эндәшәләр, әллә каян, ерактан, бөгелә-сыгыла сәламләп китәләр иде. Әнием оста җөйче иде, Баграж сылуларына чуклы-чәчәкле түшле, бәбәй итәкле күлмәкләр тегеп киертә башлагач, аның абруе тагын да үсте.

**Их, ул балачак хатирәләре!..**

Исемдә: тәбәнәк кенә, йомры гына ике малай, әтинең бертуган абзыйсы Мәхүбрахман абыйның улы, яшьтәшем Максут белән, алар капкасыннан ишегалдына кереп киләбез. Куллар артта, йөзләр җитди, авызлар йомык. Әниләр безгә карыйлар да башта... кычкырып көләләр! Ә аннан соң кычытканга үреләләр. Тикшереп карасак, икебезнең дә түшләр сап-сары икән... Ни хикмәттер, дүрт яшьләрдә чакта икебез дә чи кукәй эчәргә ярата торган идек. Гел-гел ояга менәргә

әниләр рөхсәт итмәгәндер шул, ара-тирә күршеләрнең тавык ояларына да походка чыкканбыздыр... Шуны уйладым да мәшһүр шагыйребез Һади Такташның «Мокамай йомырка урлаган»[1] дигән тәүге шигыренең юллары искә төшә. Һәр Мокамайның Әйшә тәтәе була: балачакта татыган «кычыткан себеркеләр» ул чакта урлашмаска өйрәткән әче сабак була торган иде.

Такташның беренче такмагы Мокамай турында булса, минем чыгарган беренче такмагым – шигъри юлларым – хәтердә калмаган, соңгы бер юлы гына исемдә... Ул бөдрә йонлы, тере күзле шук бәрәннәргә багышланган иде... «Идәнгә шомырт коя» иде аның соңгы юлы... баштагы юллары «Яфрак ярата бәрәннәр... тамаклары тиз туя... тамак туйгач, сикергәләп, идәнгә шомырт коя» булды шикелле...

Аеруча истә калган мизгелләрнең берсе – русларның Пасха бәйрәме. Ул көнне Баграж – керәшен авылы гөж килеп тора. Караңгылы-яктылы бала-чагалар күкәй җыялар. Йорттан йортка кереп, минем дә күкәй җыясы килә. Тик әни мине чыгармый: «Без – татар, мөселманнар»,– ди ул. Мин, аңлап бетермәсәм дә, татар икәнлегемне, керәшеннәрдән аермамны сизә башладым. Су коеныргга буа алдына төшсәк, малайлар, миңа карап, чыр-чыр көләләр, усалраклар:

Татар, татар – тарама,
Кермә безнең арага.
Кысылырсың, үләрсең –
Биш тиен акча түләрсең...–

дип җыр әйтәләр.

Усал малайларның авызын томаларлык такмак чыгарасым килә, барып кына чыкмый, җавап итеп кайдадыр отып алган җырны кабатлыйм:

Керәшен, керәшен – керкәле,
Баш түбәсе серкәле.

...Балачакның бәйрәме – кунакка бару иде. Кунак дигәндә, мин бик җәһәт идем. Яңа юллар, ят авыллар, сәер җирләр... Һәммә тараф серле, кызыклы. Ә мин – сергә тартыла торган тере малай идем...

---

[1] Һ. Такташның «Дыр-дыр, дырабан» шигыре (1907) турында сүз бара.

Әндриян дәдәйләр Федот детдомында озак тормадылар. Багражга кайттылар. Без гаиләбез белән Урта урамның буш өенә күчтек. Аның хуҗалары кая киткән булгандыр – хәтерләмим, мәгәр аларны да бер-бер нужа, бәхетсезлек күчереп йөрткәндер, дип уйлыйм.

Әйе, балачак хатирәләре, әкрен аккан, өзек-өзек ак болытлар кебек, истәлекләр бер-берсенә ялганмыйлар, әллә кайда, серле сукмакларда уралып, еракта, томанлы офыклар артында тынып калган вакыйгалар һичкайчан да бер-берсенә тоташа алмыйлар. Алсу шәүлә дә кебек алар, таңда яңгыраган сак җыр да кебек. Кайчан булып үткәннәрен өзеп әйтеп тә булмый. Балачак хәсрәтне белми, ә вакыт белән янәшә яшәү хәсрәт килгән көннән генә башлана.

**Иҗат, тәхет, тәнкыйть һәм... хакимият**

– *Мәгълүм гыйбарә: әдәбият ул – тормышның көзгесе. Ни генә булмасын, ул заман белән бергә атлый. Сез, Аяз ага, әдәбиятның үсешен һәрвакыт күзәтеп барасыз. Татар әдәбияты, аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге хакында уйланганда, Сезне күбрәк ниләр борчый, хафага сала?*

– Дөресен әйткәндә, әдәбият хакында фикерләремне чыгарып салырга куркам. Чөнки әдәбиятка мин бик берьяклы карыйм. Әйтик, мәктәп дәреслекләренә кергән, мактап, күкләргә чөеп йөртелә торган бик күп әсәрләрне мин кабул итмим. Мәсәлән, Габдрахман Әпсәләмов әсәрләрендә Ибраһимны – Игнат дип, Сәләхетдинне – Сергей дип үзгәртеп чыксаң, аның чын татар әсәре булуына сагаеп каласың.

Әдәбиятның нигезендә миллилек ята. Милли булмаган әдәбият – фальсификация ул. Әгәр язучы татар халкының төбенә төшә алмаган икән, аның яшәеш рәвеше белән рухланмаган икән, татар халкына мәхәббәте юк икән – ул инде татар әдибе түгел. Бу уңайдан мин ике замандашымны – Әмирхан Еники белән Мөхәммәт Мәһдиевне аерып куям, аларны зур талантлар дип саныйм.

Мин үзем мәктәпкә якын булмадым. Әсәрләремне мәктәп программаларына беркайчан да кертмәделәр. Дәреслекләрдә һаман да шул завод-фабрикалар, нефтьчеләр турында язылган әсәрләр өстенлек итә. Минем каләмдәшләремә авыр сүз әйтә-

сем килми. Язмыш язучыны әдәбиятка ничек әзерләгән, ул шулай яза инде. Ләкин вакыт узар, аларның бәяләре төшәр. Хаклык гомер-гомергә, авырлык белән булса да, җиңә барган ул.

«Йәгез, бер дога!» минем соңгы китабым булды. 1994 елда инсульт кичердем. Шуннан бирле эш азрак әкренәйде. Замана да үзгәрде. Укучы да калмады. Татар халкы аракыга һәм телевизорга сатылды. Авылларда ничектер, шәһәрдә татар китабын укучылар көннән-көн азая, кызганычка каршы. Мин – бераз төшенкерәк күңелле кеше. Шуңадырмы, әсәрләремдә күбрәк кайгы-хәсрәт, замананың катлаулы мәсьәләләре, татар халкына тарих китергән бәла-казалар турында язарга тырыштым. Заманында эшсез торуны мин күз алдыма да китерми идем. Эш минем бөтен барлыгым – ялым да, куанычым да иде.

...Әдәбият ул үлчәү тәлинкәсе кебек – бер күтәрелә, бер төшә. Бүген, мәсәлән, татар әдәбияты шактый катлаулы чор кичерә. Бик зур титаннар арабыздан китте. Мин дә бик аз язам. Хәзер гомер буе язучы булырга хыялланган һәм язганын кешегә күрсәтергә оялып йөргән бер төркем «каләм осталары» калкып чыкты. Район типографияләрендә «әсәрләр»-ен бастырып чыгаралар да Язучылар берлегенә әгъзалыкка дәгъва кылалар. Өстәвенә, алар бик әрсезләр дә әле. Таләпләр йомшарды. Быел «Казан» шифаханәсендә дәваланып йөргәндә, шунда эшләүче берәү: «Мин – Язучылар берлеге әгъзасы»,– дигәч шаккаттым...

Бүген рус әдәбияты да, татар, башкорт әдәбиятлары да торгынлык кичерә. Рус әдәбияты нәрсә бәрабәренә яши? Русның чит илдә зур әдәбияты бар иде. Ул шуның хисабына яши. Безнең дә Гаяз Исхакыйларыбыз, Садри Максудиларыбыз кайтты. Ләкин алар халык күңеленә чынлап кайтып җиттеләр микән? Аларны кабул итә торган халык калдымы? Белмим... Белмим...

Бу – күчеш чоры. Мин беркайчан да өметемне өзмим. Әгәр татар укытучылары, татар мәктәпләре яшәсә, яңа талантларыбыз калкып чыгар әле. Милләтнең күңеле төшенке булса да, ул беркайчан да бөтенләй буш була алмый.

– *Аяз ага, нинди генә чор булмасын, тәнкыйть, әдәбиятның юл күрсәтүче маягы булып, гел алгы сафта барган. Сез*

*мәкаләләрегездә тәнкыйтьнең кирәклеге, аның әдәбиятны үстерүдәге урыны турында еш яздыгыз. Ә үзегезне иҗат гомерегездә тәнкыйть артык иркәләмәде бугай...*

— Мине изәргә бик тырыштылар. Ләкин мин алай гына бирешә торган булмадым. Архивымда бер папкам бар. Ул «Мин гомер буе тәнкыйтьчеләргә азык булдым» дип атала. Мине алар рәхәтләнеп, ләззәтләнеп, тирән канәгатьләнү белән «тәнкыйтьләделәр». Егерме ел дәвамында обком да иҗатымны тискәре яктан бәяләгән мәкаләләр язуда аларга һәрьяктан таяныч булды. Иң беренче сәхнә әсәрем — «Җиз кыңгырау» дөнья күргәч, редакциягә, аны тәнкыйтьләп, 35 бәяләмә килә. Кем генә «кыйнамады» Аяз Гыйләҗевне, сыер савучы да, төзүче дә, тегүче дә... бар иде алар арасында. Ә «Өч аршын җир» повестем «Совет әдәбияты»нда дөнья күргәч, аны тәнкыйть утына тоттылар. Журналның баш мөхәррире Газиз Мөхәммәтшинны[1] хәтта, Советка каршы әсәр бастыргансың, дип, көн-төн обкомга чакырдылар. Ә инде әсәрне китап итеп бастырып чыгару? Шушы вакыйгадан соң аны нәшрият якын да китермәде. Әсәр Мәскәүдә Искәндәр Гыйзәтуллин тәрҗемәсендә «Дружба народов» журналында рус телендә басылып чыкты һәм, елның иң әйбәт әсәре буларак, махсус премиягә дә лаек булды. Хәтта ул Мәскәүдә аерым китап булып нәшер дә ителде. Шуннан соң ун еллар үткәч кенә, әлеге әсәрем җыентыгыма кертелде.

Фәрваз Миңнуллинның дүрттомлыгыма язган мәкаләсендә шундый юллар бар: «Чын әдип, чын язучы тәнкыйтькә әйләнеп тә карамый, ә көлемсерәп кенә куя». Мин дә, нәкъ Фәрвазча, шундыйрак принцип белән яшәргә тырыштым.

— *Сез әңгәмәләрегезнең берсендә, ярым шаярыпмы, «прозаик буларак тәнкыйтьли башласалар, драматургиягә күчеп тордым, драматург буларак «дөмбәсләсәләр», прозага күчтем» дип сөйләгән идегез. Шулай да, әйтегез әле, кайсы жанрны иярләү җиңелрәк булды: прозанымы, әллә драматургиянеме?*

— Чын күңелдән әйткәндә, кырыктан артык пьеса язсам да, мин драматург була алмадым. Мин сәхнәне тормышны өйрәнә торган университет дип аңладым. Аны халыкны тәр-

[1] Газиз Фазыл улы Мөхәммәтшин (1932–1972) — язучы. 1964–1965 елларда — «Совет әдәбияты» журналының баш мөхәррире.

бияләү чарасы итеп кабул иттем. Шуңа күрә Чехов, Шоу, Ибсен кебек акыллы драматургларны үземә остаз итеп алдым. Баксаң, театр тамаша икән ул. Мин тамаша кора белмәдем.

— *Сез көнчеме?*

— Юк. Гомер буе бары тик Мөхәммәт Мәһдиевтән «татар авылы тормышын яхшы белә» дип кенә, сокланып көнләштем. Мин бит, алдарак әйткәнчә, керәшен авылында яшәдем: татар халкының йолаларын, гореф-гадәтләрен күреп үсмәгәнгә гел пошына идем.

— *Мөхәммәт Мәһдиев, дигәннән, Сез аның иҗатына һәрвакыт игътибарлы булдыгыз. Хәтта тирән аналитик мәкаләгез дә дөнья күрде. Ә Мөхәммәт ага — Сезнең иҗат хакында ләм-мим...*

— Мөхәммәт ул замандашларыннан берәүнең иҗаты хакында да сүз әйтмәде. Сәбәбен бер Ходай үзе генә белә.

— *Иҗат һәм тәхет... Болар арасында уртаклык бармы?*

— Болар арасында уртаклык бик күпләрдә бар. Чөнки күпләр иҗатларын тәхеткә баскыч итеп кабул иттеләр һәм хәзер дә шулай яшиләр. Мин үзем беркайчан да ниндидер мөнбәрләргә үрмәләмәдем, аңа омтылмадым да. Хакимиятнең никадәр куркыныч көч икәнен бик күптәннән аңладым. Шулай булмаса, төрмәгә дә керми идем, баштан кичкәннәрем хакында документаль әсәр дә язмый идем. Төрмә минем өчен зур бәхет булды. Ул миңа тормышның нәрсә икәнен аңлатты. Ә менә Хәсән ага Туфан, мәсәлән, шигъри күңелле кеше буларак, төрмәнең нәрсә икәнен аңлый да алмады. Зинданнан чыккач та, «Ал мине, партия!» дип, коммунистларга мәдхия җырлады. Ибраһим ага Салахов[1] та бер телевизион тапшырудагы әңгәмәсендә: «Мин утырып чыктым, әмма бу режимны каралтмадым, аны каһәрләмәдем»,— ди. Беркатлылык инде, беркатлылык... Татарның саф күңеллелеге, самимилеге...

— *Аяз ага, Татарстанның халык язучысы, республикабызның Г. Тукай премиясе иясе буларак, бер фикерегез белән уртаклашсагыз иде: менә инде ничәмә еллардан бирле, «татар мәдәния-*

---

[1] Ибраһим Низам улы Салахов (1911—1998) — язучы. Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1990), Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1992).

*тенә игътибар юк, мәдәният әһелләренең матди хәлләре авыр», дип чаң сугабыз. Ә алга китеш сизелми...*

– Моның сәбәбе бик гади – татарлык. Чөнки татар әдәбиятына тиешле игътибар җитми кебек. Милли байлыгыбыз һәрвакыт милләткә хезмәт итәме соң?! Балаларым карамаса, мин дә бүген – урамда хәер сорашып утырырга тиешле кеше. Чөнки пенсия акчасы дару алырга да җитми бит ул. Шушы булдымы дәүләт?! Шушы булдымы киләчәк?!

Әдәбиятка сан булмау, өметсез киләчәк – болар барысы да язучы йөрәге аша уза. Мораль яктан аны какшата, сәламәтлегенә зур зыян сала. Мин үзем, мәсәлән, хакимият белән беркайчан да килешмәдем. Шуның өчен башыма гел сугып тордылар. Чыккан китапларым да, хәтта нәшриятта Фәрваз Миңнуллин кебек таянычларым, яклаучыларым булса да, гомер буе тәмәке кәгазеннән булды.

– *Сер булмаса, әйтегез әле, моңарчы дөнья күрмәгән мирасыгыз күпме?*

– 30 том. Мин, аларны киштәгә тезеп куеп, өсләренә «100 еллыгыма гына ачып карый аласыз» дип язып куйдым. Бөтен архивым Нәкыя кулында кала. Барысы да аның ихтыярында.

## Балта кем кулында?

– *Аяз ага, чын язучы – милләтнең намусы, йөз аклыгы. Сезне бүген милләт мәсьәләсендә күбрәк нәрсәләр борчый, шомландыра, уйга сала? Татарның язмышы кем кулында ул? Бармы аның киләчәге?*

– Әлбәттә, соңгы ун ел эчендә «Без милләт өчен кайгырабыз! Милләт безнең кулда!» дип шәрран ярып сөйләүче аерым кешеләр төркеме калкып чыкты. Ләкин күпме генә сөйләсәләр дә, татар язмышы мәктәп кулында. Минем хатыным Нәкыя гомере буе мәктәптә укытты. Сентябрь аенда укулар башлангач, Нәкыя мәктәптән кайтып керүгә, беренче соравым шул була торган иде: «Класста ничә Айрат? Ничә Айдар? Ничә Руслан? Ничә Альбина бар?» Кызганыч, пәйгамбәрләребезнең исемнәрен ишетергә туры килмәде. Элек бит Коръәндәге исемнәр генә исем булып саналганнар. Исем бит ул күп нәрсә хакында сөйли. Күз алдына китереп карагыз: Президентыбыз, Минтимер булмыйча, Айдар булды, ди.

Әти-әнисе, аның киләчәктәге язмышын билгеләп, күңелләреннән сизенеп, нинди затлы һәм көчле исем кушканнар.

Язучыларыбыз да «милләт» дип «сайрарга» оста. Ә менә күз салсаң, бик күп татар язучыларының балалары ана телләрен белмиләр. Оныкларын әйткән дә юк. Күп кенә язучыларның хатыннары, үзләре авыл хатыннары булсалар да, оныклары белән вата-җимерә русча пупалыйлар. Русчаны өйрәнү җиңел бит ул. Чөнки радио-телевидение 24 сәгать буе рус телендә сөйли. Тарих безне шундый язмышка дучар иткән икән, нишләмәк кирәк.

Без Россиягә ике миллиард ярым тонна нефть бирдек. Ә ул кемгә хезмәт итте?!

Без башкаларны яшәтәбез. Без – донорлар. Шуның өчен без горур булырга да өйрәнергә тиешбез. Татар икән – ул тырыш, эшлекле. Татар авылы, ярлы булса да, чиста-пөхтә ул. Ә татар хатыннары кебекләре дөньяда юк! Шуның өчен дә элек үзбәк, казах, кыргыз аксөякләре хатынлыкка татар кызларын сайлаганнар. Бу – безнең милли горурлыгыбыз түгелме?!

*– Милләт, аның киләчәге турында сүз алып барганда, Татарстанның мөстәкыйльлеге хакында да фикерләрегезне ишетәсе килгән иде. Бу уңайдан Сезнең өметләрегез ни дәрәҗәдә акланды?*

– «Мөстәкыйльлек» дигән сүзне ишетсәм, минем көләсем килә башлый. Хәер, «мөстәкыйльлек» дип, моннан ун ел элек лаф ора башлаганда, да өметләрем нык түгел иде. Чөнки империядә яшәгән милләтнең киләчәге юк.

*– Сез – узган гасырдагы бик күп вакыйгаларның тере шаһиты. Күз алдыгызда берничә мәртәбә алфавит та алышынды. Шул уңайдан сорыйм әле: Сез латинга күчүгә ничек карыйсыз?*

– Мин шактый шигәеп карыйм бу мәсьәләгә. Латинга күчсәк, без үзебезнең күпьеллык тарихыбызны югалтачакбыз. Хәзер төрек теленә нигезләнгән алфавит белән шигырьләр бастырып чыгаралар. Мин аларны укый алмыйм һәм инде үзләштермәячәкмен дә. Безнең бөтен тел үзенчәлекләренә җавап бирә торган әлифбабыз бар иде – яңалиф. Мин яңалифкә кайту ягында.

*– Аяз ага, фараз кылып карыйк әле: татар халкының язмышын тагын алты-җиде елдан ничек күз алдына китерәсез?*

– Мин күрәзәче түгел. Шуны гына әйтә алам: хакимияткә Сталин чоры яңадан кайтыр кебек. Бүген балта куркыныч кешеләр кулында.

– *Ә чечен вакыйгасы, сезнеңчә, кайчан тәмамланыр?*

– Беркайчан да тәмамланмас. Менә ничә елдан бирле чеченнарны кыралар, ә алар һаман бетми, һаман көрәшә. Безнең ил бит сугышмыйча тора алмый. Аңа һәрвакыт кан кою кирәк. Сугышмый нишләсен, әнә соңгы өч-дүрт ай эчендә генә дә хәрбиләрнең хезмәт хакларын шактый арттырдылар ич...

– *Моннан берничә ел элек Сезне Казанда югалтып тордык. Зәйнең элеккеге хакимият башлыгы Рәшит Сәет улы Хәмәдиев Сезгә туган якларыгызда яшәргә мөмкинлекләр тудырды. Зәйне үз итмәдегезме, Казан сагындырдымы, нишләптер кайтырга булдыгыз?*

– Балалар монда. Картайдык. Кайттык. Зәй безгә һәрьяктан да бик нык ярдәм итте. Мең рәхмәт аларга! Рәшит – чын мәгънәсендә татар мәдәниятенең сакчысы. Аның белмәгән, укымаган әсәре юк. Без бер-беребезне шуның кадәр тулыландыра идек. Мин аның белән танышуымнан чиксез бәхетлемен. Рәшит дустым, Чаллы шәһәре хакимияте башлыгы булуына карамастан, хәзер дә игътибарыннан ташламый. Зәйдә үткән гомеребезне матур бер төш итеп кенә күз алдына китерәбез.

– *Узган гомерегезнең кайсы чорын күбрәк сагынасыз?*

– Мин узган гомеремнең иң авыр елларын да сагынам.

***

Милләтнең иң зур байлыгы – ХӘТЕР. Уртак хәтерсез милләтләр милләт булудан туктап, гавам, халык төркеменә әйләнәләр. Уртак ХӘТЕР уртак җир булганда гына саклanaдыр, мөгаен... Тарихның иң аяусыз мизгелләрендә империяләр, тираннар ХӘТЕРнең үз властьларына комачаулаган өлешен таптап изәргә, күмәргә тырышканнар. ХӘТЕР – чәрексез хәзинә. Октябрь революциясеннән соң усаллыкта бары тик фашистлар партиясе белән генә янәшә куярлык коммунистларның төп эше шул булды: алар, көчләп-юлдап, куркытып, асып, кисеп, ялган вәгъдәләр биреп, милләтләрнең ХӘ-

ТЕРен аста, коммунистик кара дулкын астында калдырдылар. Милли ХӘТЕР – бары тик үз җирендә бердәм булып яшәгәндә генә саклана ала һәм буыннар дисбесенең бөтенлеген, тулылыгын саклый *(«Йәгез, бер дога!»дан)*.

***

МИЛЛИ ХИС! Адәмнең меңгә тармаклана алган җанында аннан да кайнар, аннан да сизгер, аннан да нәзек берәр хис бармы икән?! Адәм баласы үз ындыры артыннан еракка чыгып йөрмәскә дә мөмкин, аның Достоевский, Куинджи[1], Веласкес[2], Раблеларны[3] ишетмәве дә бик-бик ихтимал, ул Шаляпинның[4] күкләр күкрәтер тавышыннан Собиновның[5] былбыл моңнарын аера да алмый торгандыр, аның омаркыслалардан авыз иткәне дә юктыр, мәгәр һәркемнең җанын беркетеп торучы бөек бер мәгънә бар – ул аның МИЛЛИ ХИСе.

О-о, җан бизәге булган МИЛЛИ ХИСЛӘРгә саксыз кагыла күрмә! МИЛЛИ ХИС – ике яклы пычак ул. Ул, бөек, нәзек булган кебек, аяусыз, куркыныч вә дәһшәтле дә була ала!.. МИЛЛИ ХИСЛӘРнең нечкәлеге белән еш кына шовинистлар, диктаторлар, илбасарлар оста, мәкерле рәвештә файдалана *(«Йәгез, бер дога!»дан)*.

---

[1] Архип Иванович Куинджи (1841–1910) – рус һәм украин рәссамы, пейзаж сәнгате остасы.

[2] Диего Родригес де Сильва-и-Веласкес (1599–1660) – испан рәссамы.

[3] Франсуа Рабле (1494–1553) – Ренессанс чоры француз язучыларының берсе, «Гаргантюа и Пантагрюэль» романы авторы буларак билгеле.

[4] Фёдор Иванович Шаляпин (1873–1938) – рус опера һәм камера җырчысы, Зур һәм Мариинский театрлар солисты.

[5] Леонид Витальевич Собинов (1872–1934) – рус опера җырчысы, рус классик вокал мәктәбенең бер вәкиле.

## «Авылда яшәсәк, без 10 малай алып кайтасы идек»[1]

*(Э. Вәлиуллина әңгәмәсе)*

Аяз абый Гыйләҗев белән без республика клиник сырхауханәсендә очраштык. Сөекле язучыбыз 7нче катның 12нче палатасында җәмәгате Нәкыя ханым белән дәваланып ята иде. Әдәбиятыбыз аксакалларының берсе булган Аяз абый сырхауханәдә дә иҗат планнары белән яши, милләт турында борчыла һәм... 10 малай турында хыяллана.

*– Күңел түреннән өзелеп төшкән иҗат җимешләренең һәркайсы кадерле һәм якындыр. Шулай да, аеруча яраткан әсәрләрегез бармы?*

– Кайсындыр яратам дип аерып әйтү бик кыен, чөнки һәрбер әсәр күңел газапларында туа бит. Шулай да, «Өч аршын җир», «Язгы кәрваннар», «Яра» повестьларын алга куяр идем.

*– Аяз абый, тылсымчы килеп, иң зур теләкләрегезне үтим, дисә?*

– Нәкыям бәхетле, озын гомерле булсын, чөнки әле башкарылмаган эшләремне ахырынача ул җиткерәчәк. Күп эшләрем кульязма хәлендә ярты юлда кала. Аннары, илебез имин булып, татар халкы бәхетле яшәсен иде. Безнең халыкның тулы бәхетне беркайчан да татыганы юк бит. Империя йогынтысында яшәгән халык бәхетле була алмый. Без кайвакыт: «Халкыбыз алай, халкыбыз болай», – дип гаепләп чыгабыз. Коллык дәрәҗәсенә җиткерелгән, дине тапталган, теле киселгән булуына да карамастан бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән татар халкына сокланырга кирәк. Андорра кебек бәләкәй дәүләтләр урыслар янәшәсендә булса, алар күптән йотылган булыр иде инде. Шуңа, татар халкын гаепләргә урын юк. Татарларның язмышы әле хәзер дә хәл ителмәгән. Менә шул борчый. Тылсымчыга: «Балаларым үз илләрендә бәхетле булсын», – дип әйтер идем.

*– Ә тормышыгызда яки язмышыгызда берәр нәрсәне үзгәртү, төзәтү мөмкинлеге туса?*

---

[1] Гыйләҗев А. Авылда яшәсәк, без 10 малай алып кайтасы идек / Э. Вәлиуллина әңгәмәсе // Татарстан яшьләре. – 2001. – № 41. – 2 октябрь.

– Алай әлләни үзгәртмәс идем. Ә менә авылда яшәгән булсак, без Нәкыя белән 10 малай алып кайткан булыр идек. Нәкыя – яхшы ана, көчле кеше. Ул хәтта ун-унбиш бала да тәрбияли алыр иде.

*(Шуннан әңгәмәгә Нәкыя ханым үзе кушыла*).

– Аяз тормышын үзгәртү мөмкинлеге булса, хәтта төрмәдә утырган вакытларын да сызып ташламас иде. «Төрмәдә утырмаган булсам, дөньяны начар белер идем»,– ди ул еш кына. Чөнки аның өчен төрмә – тормыш университеты булды. «Сугышта әсир төшкән, унышар телдә сөйләшүче японнар, мадьярлар, немецлар, латышлар һ.б. күргәч, аралашкач, мин үзебезнең ни дәрәҗәдә артта калганны белдем»,– ди ул.

– *Көннең яисә елның кайсы фасылында күбрәк языла?*

– Кайбер язучылар «Мин илһам килгәнне көтәм»,– дип әйтергә ярата. Ә мин беркайчан да илһамны көтмәдем (*елмая*). Гомерем буе эш аты булдым, өстәл янына килеп язу машинкасы артына утыруга, кичтән өзелеп калган фикерләр, тыгызланып, кәгазьгә төшә башлыйлар иде. Гомер буе иртән эшләдем. Күп түгел, бишәр бит. Ә сәгать уннарда шул биш битне күчереп ала идем. Мин гомер буе машинкада эшләдем. Биш машинка туздырдым. Шунысы да бар: машинка тәртипкә чакыра, эшкә өнди.

– *Татар әдәбиятында аерым бер урын тоткан Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев кебекләргә алмашка килүче яшьләр бармы?*

– Бөтен әсәрләрне дә укып бара алмыйм, шуңа әйтү кыен. Шулай да, соңгы елларда өметлеләр күренә.

– *Латин графикасына күчүгә мөнәсәбәтегез ничек? Күпьеллык мирасыбыз югалыр, дип курыкмыйсызмы?*

– Минем бу турыда мәкаләм дә басылды. Латинга күчәргә кирәк, әлбәттә. Мирасның бер өлеше югалыр, ләкин кайчан да булса бер күчәргә кирәк бит инде. Шушы көннәрдә матбугат битләрендә укыдым, профессор Арутюнов та: «Татарлар – бөтендөнья цивилизациясендә иң алда барган халык. Русия составындагы халык арасында да алар алдагылар. Татарлар гына түгел, урыслар да латинга күчәчәкләр»,– ди бит.

– *Буш вакытларыгызны ничек үткәрергә яратасыз?*

– Буш вакыт бик сирәк була инде ул. Җәен Иделгә балыкка йөрергә, гөмбә җыярга яратам. Телевизордан яңалыклар, футбол карыйм.

– *Аяз абый, татар әдәбиятының киләчәген ничек күзаллыйсыз?*

– Татар әдәбиятының киләчәге татар халкының һәм татар теленең язмышы белән бәйле. Татар әдәбиятын якты, олы итеп күрәсем килә, ләкин, турысын әйткән вакытта, киләчәккә шактый шикләнеп карыйм.

– *«Яңа гына табадан төшкән» әсәрләрегезне иң беренче кем укый?*

– Әсәр ул – майлы коймак түгел (*кырысланып китә*). Мин шул «табадан төшкән» дигән ясалма сүзтезмәне кабул итә алмыйм. Нигездә, беркем дә укымый. Соңгы елларда Нәкыя апаң машинкада баса. Хатын әсәр укучы түгел ул, ә булышучы. Мин үзем дә: «Менә әсәр яздым, Нәкыя», – дип, төчеләнеп, әсәр китергәнем юк. Һәр нәрсә үз чираты белән. Укый, фикерләрен әйтә.

– *Ә кеше фикере буенча әсәрләрегезне үзгәрткән очраклар булмадымы?*

– Мин беркайчан да кеше фикере белән эшләмәдем, яшәмәдем. Проза өстенә пьесалар да язган кеше бит мин. Драматургия мине яшәтә, тик асылда мин драматург түгел. Хәзерге асылым булса, мин пьесалар язып маташмас идем.

– *Иң бәхетле көнегез?*

– Өйләнеп, менә бу кызны *(яратып хатынына карый*) алып кайтуым – иң бәхетле көн! 3 улым туды – бәхетле көннәрем! Дөнья селкетеп, кешегә баш имичә, максатларга ирешеп бару – үзе зур бәхет!

# Көндәлекләр

## «Уйларның төрмәсеннән котылу» ысулы

(А. Гыйләҗев)

Беренче көндәлекләрен язучы[1] мәктәп елларында ук яза башлый. Алар табылмый, чөнки А. Гыйләҗевнең әтисе, улының кулга алынуын белүгә, аларны юк итә. Язучы көндәлекләрен гади көнкүреш язмалары белән чуарлауга тискәре карый. Иҗатының башлангыч чорында көндәлекләр ролен язучының хатынына язган хатлары үтәп килә. 1967 елның 9 декабрендә, А. Гыйләҗев көндәлекләрнең язучыларның иҗади биографиясендә әһәмиятле роль уйнаганлыгын аңлап алгач, аның аңында кискен борылыш була. Шул вакыттан А. Гыйләҗев, «мизгелне тотып калу, мәңгеләштерү» өчен, көндәлекләр яза башлый. Әкренләп, көндәлекләр аның әдәби мирасының аерылгысыз бер өлешенә әверелә. Аларда язучы фикеренең үсеше, тормыш хакындагы уйланулары, иҗтимагый-әхлакый эзләнүләре чагылыш таба. Көн дә көндәлеккә мөрәҗәгать итеп, язмалар теркәп бару язучы өчен беркайчан да үзмаксат булмый. А. Гыйләҗев көндәлегенә әйтер сүзе, язар фикере булганда гына, вакыт-вакыт мөрәҗәгать итә. 1980 елдан исә көндәлекләрнең характеры үзгәрә. Язучы хатларында гына түгел, көндәлекләрендә дә «үз заманының протоколчысына»[2] әверелергә тели.

---

[1] А. Гыйләҗевнең көндәлекләренең зур күпчелеге 6 томлы «Сайланма әсәрләр»дә (2013–2016) дөнья күрә: Кара: 3 т.– 375–386 б., 4 т.– 181–210 б., 5 т.– 116–150, 6 т.– 83–255, 307–532 б.

[2] Цецилия Кин язучы Александр Гладковны шулай атый. Тулырак мәгълүмат.: Гладков А. Дневники // Новый мир.– 2014.– № 1. С. 142–162.

А. Гыйләҗевнең кызыксыну даирәсе әдәбият һәм гаиләсе белән генә чикләнми – һәм бу куандыра да. Көндәлекләрендә ул тормышның төрле якларына игътибар бирә. Укыган китаплары, газета-журналлардагы мәкаләләре, караган спектакль-фильмнары, акыллы әңмәдәшләр белән очрашулары, тормышындагы вакыйгалар, гыйбрәтле хәлләр, үзенең һәм танышларының нинди ризыклар яратуы хакында яза. Аны фәнни ачышлар, бигрәк тә татар халкы вәкилләренең теге яки бу өлкәгә керткән өлеше кызыксындыра. А. Гыйләҗев илдәге һәм дөньядагы вакыйгаларны күзәтеп, теркәп бара, хөкүмәтнең һәм оппозицион көчләрнең гамәлләрен бәяли. Көндәлекләрендә язучы билгеле бер вакыт арасында кылган гамәлләренә, иҗатына, үз-үзенә хисап бирә, киләчәккә булган планнарын барлый. Язучының үз нәсел шәҗәрәсен төзергә омтылуы зур кызыксыну уята. Аерым язмалар кайвакыт әдәби портретлар һәм некрологлар төсен ала. А. Гыйләҗев замандашларының исемнәрен мәңгеләштерергә, киләчәк буыннарга аларның кабатланмас характер сыйфатларын, үзенчәлекле карашларын җиткерергә, иҗатларына булган мөнәсәбәтен динамикада сурәтләргә омтыла. Көндәлекләренең әһәмиятле өлешен туган як табигатенә, туган илгә мәдхия булып торган поэтик сурәтләүләр тәшкил итә. 1992–1997 елларда көндәлек алып бару А. Гыйләҗевнең бурычына, кыйммәтле шәхси актына әверелә. Алга таба, авырып китү сәбәпле, әдип язмаларны мөстәкыйль рәвештә теркәп бара алмый башлый, һәм бу эш авырая.

*Миләүшә Хәбетдинова*

## Мин шулай уйлыйм[1]

1 ноябрь, 1980 ел

Рига–Дубулты

Сөенәм! Казаннан китеп торуыма да, монда килүемә дә сөенәм, бу иҗат йортында беренче мәртәбә булуым бит. Күңелле урын, шәп урын, уйландыра торган урын. Диңгез ярында ялгыз калу сирәк кешегә эләгә торгандыр, диңгез яры – вокзал шикелле бит ул, бик аз вакытка гына буш кала. Ә хәзер диңгез яры буш... Күз күреме кадәр җиргә сузылган комлык. Асфальт түгел, таш түгел, яфрак түшәгән урман сукмагы кебек аякны иркәли. Барасың да барасың. Бүген диңгез ягымлы. Кемнәрдер, сихри кунакчыл көчләр, тирәнлектән, ерактан этеп китерәләр дә синең алдыңа бер-бер артлы ак белән читләнгән келәмнәрне җәяләр... Диңгез – җан ияләренең бишеге. Һәм колакка туктаусыз бишек җыры агып тора. Син беләсеңме микән, диңгез суы белән кеше канының химик составы бер үк. Җан иясе диңгездә яралган. Мин моны бер чакта да онытмыйм. Кайчагында борылып, олылап, диңгезгә, дулкыннарга, акчарлакларга баш иясе килә. Иреннәрдә тоз тәме, озак йөргәч, тамак төбендә дә тозы сизелә. Күкрәк киңәя, кан тамырлары киңәя, үзеңне кеше итеп тоя башлыйсың. Мин гел су ягасыннан ук барам, язучы кеше дулкыннар белән янәшә һәм пычак йөзе кебек үткер язмышта яшәргә тиеш түгелмени? Сөенәм! Исән булуыма да сөенәм, кеше булуыма да сөенәм, илнең, күкнең тыныч булуына да сөенәм. Язучы кеше әнә шул тирән сөенечен кешеләр белән уртаклашу бәхетенә ия. Кешеләрне сөенергә өйрәтү – безнең бурыч. Мин шулай уйлап барам. Күз алларым, якты уйларым шушы диңгез кебек әллә кая офыкларга барып җитә, офык артында минем туган ягым, Казан, халкым, сез – якын дусларым, фикердәшләрем, көрәштәшләрем. Бүген ялгызлыгыма сөенәм. Чөнки минем уйларымны беркем бүлдерми, уйларым үзем теләгән якка талгын гына ага. Зиһенемнең ачык, фикеремнең төгәл булуына да сөенәм. Нигә кемнәрдер минем әсәрләрдән

---

[1] Гыйләҗәв А. Мин шулай уйлыйм [А. Гыйләҗевның үзенең иҗатында очраган кыенлыклар турында. 1980 елның ноябрьдә язылган мәкаләсе] // Ватаным Татарстан.– 2005.– 11 март.

кара ишарәләр табарга тырышалар икән? Хәтта син дә, кайчагында, нидәндер шикләнеп куясың...

Нидән шикләнергә? Шушы яшемә җитеп, мин күңелемнең күпме серләрен китапларым аша ачып өлгермәдеммени? Теге яки бу шикләнүләргә баш биреп түгел, язучының иҗатын тоташ агым, хәрәкәт итеп карарга кирәк. Иҗатны бөтен һәм тере организм итеп караганда гына, аны тудыручыга чын бәһане бирергә мөмкин. Дөрес, бүген, әле язучының иҗат юлы тукталмаганда, соңгы сүзне әйтергә ашыкмаска да кирәк. Әмма акыллы һәм җете күзле тәнкыйтьче язучы үзе исән чакта ук ул тудырган агымның тирәнлеген, киңлеген, көчен үлчи ала һәм, ниндидер бер дәрәҗәдә, аның киләчәген дә билгели.

Ә какшамас хөкемне вакыт һәм зур сынаулар гына бирә ала!

Тукай мәңгелек. Әле «мәңгелек» дип авыз тутырып әйткәндә дә без Тукайның кем икәнен ачып бетерә алганыбыз юк. Мәсәлән, Галимҗан Ибраһимов һәм Тукай мөнәсәбәтләре. Бу – бик мөһим мәсьәлә. Ни өчен Г. Ибраһимов «Тукай шагыйрьме, түгелме?» дип, үз заманында ук бөек шагыйребезне күмәргә азапланган да, ни өчен Тукай аны йолдызга карап өрүче әнчеккә тиңләгән? Хәтерем ялгышмаса, Тукайның Г. Ибраһимовка язган хатлары да булырга тиеш. Без бүген ул хатларны халыклаштырмыйбыз икән, без кемнеңдер бөеклегенә шикләнеп карыйбыз, дигән сүз. Я Тукай хаклы түгел, я Г. Ибраһимов ялгышкан...

Без Тукайны яратып укыйбыз. Тукайдан цитаталар китереп, фикерләрен куәтләгән бик күп кешеләр аның кем һәм ни өчен мәңгелек булуы турында уйлап та карамыйлар. Б. Пастернакның[1] кызыклы гына бер фикере бар. Ул болай ди: «Гений есть не что иное, как редчайший и крупнейший представитель обыкновенных, рядовых людей времени, ее БЕССМЕРТНОЕ ВЫРАЖЕНИЕ». Минем соңгы ике сүзгә ни өчен аерым басым ясавымны аңлыйсыңдыр?!

---

[1] Борис Леонидович Пастернак (1890–1960) – рус язучысы, XX гасырның иң күренекле шагыйрьләренең берсе. Нобель премиясе лауреаты (1958).

Мең еллык тарихыбызда иң якты, иң олы шәхес булган Тукайны да укып бетерә алганыбыз юк әле безнең. Әйтик, шагыйрьнең «Шүрәле» исемле кискен социаль һәм сатирик поэмасын без бүгенгәчә «балалар азыгы» дип йөртәбез һәм яшь укучыларга шулай дип тәкъдим итәбез дә.

Такташ – бөек шәхесләребезнең берсе. Аның яшьлек чоры иҗаты бигрәк тә югары бәягә хаклы. Такташның үзеннән соңгы поэзиябезгә тәэсире үлчәп бетергесез! Моңарчы без аның бу ягын да ничектер кире күренеш итебрәк саныйбыз! Бөек Дәрдемәндне без һаман «промышленник» дип газаплыйбыз! Әйтерсең лә Пушкин, Лермонтов, Державиннар[1] тубал тотып кырда иген чәчеп йөргәннәр! Әйтерсең лә Фет[2] явыз крепостник булмаган! К. Тинчуринны[3] без һаман шуклык-шаянлык драматургы итеп кенә санап йөртәбез һәм аның тиңсез уңышларының сәбәбе итеп... Сәйдәш белән уртак иҗат итү бәхетен исәплибез. Мәңгелек «Зәңгәр шәл»[4] пьесасы ул – гади күз белән караганда гына мелодраматик әсәр, хәлбуки ул татарның шул чор тормышын бөтен тулылыгы, каршылыклары, бәрелешләрен эченә алган һәм барлык социаль группаларның кискен конфликтын гаҗәеп оста гәүдәләндергән ифрат җитди пьеса. Без Тинчуринның кем икәнлеген аңларга тырышмыйбыз, иҗаты турында сүз алып барганда, аның гаҗәеп тирән прозаик икәнен онытып та куябыз. «Ак чибрик»[5] хикәясен генә ал! Бу хикәя атаклы «Сәмигулла абзый»[6], «Сәмруг кош»[7] хикәяләре белән бер дәрәҗәдә тора.

---

[1] Гавриил (Гаврила) Романович Державин (1743–1816) – күренекле рус шагыйре, дәүләт эшлеклесе, сенатор, действительный яшерен киңәшче.

[2] Афанасий Афанасьевич Фет (1820–1892) – рус шагыйре, тәрҗемәче, Санкт-Петербург Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы (1886).

[3] Кәрим Гали улы Тинчурин (1887–1938) – татар совет драматургиясенең классигы, күренекле артисты һәм режиссёры.

[4] К. Тинчуринның 1926 елда язылган әсәре.

[5] К. Тинчуринның беренче хикәясе.

[6] Ф. Әмирханның 1916 елда язылган хикәясе.

[7] Ф. Әмирхан хикәясе.

Димәк, без моңарчы әдәби хуҗалыгыбызның чын хуҗалары була алмадык әле. Без нәрсәнең кайда ятканын да, кичә кирәк булган нәрсәләрнең бүген дә бик хаҗәт булуларын уйлап бетермибез. Димәк, без мәңге мактаныч булырлык якты шәхесләребезне күңел михрабыбызга менгермәгәнбез. Һаман чикмән чабуларына ябышып, бөек кешеләребезне дә артка тартабыз, теге даһи анекдоттагыча, татарлар кайнаган сумала казанына, үзебезнең янга, чүплек базына тартып төшерергә әзер торабыз.

Мин биредә әдәбият күгебездә азмы-күпме олы исемнәре ныгып барган кайбер газиз исемнәрне атадым. Әйе, кызганычка каршы, Ф. Әмирхан, М. Галәү, Ә. Еники кебек затлы прозаикларыбызның бүгенге көнгә кадәр түребезгә менеп җитә алганы юк. Бигрәк тә М. Галәунең дөньякүләм танылырлык романнары халкыбызга чын хезмәтләрен күрсәтә алмыйча арткы планда йөриләр. Ә ул – үз чорының, үз вакытының иң катлаулы, иң мәгънәле мәсьәләләренә кыю рәвештә мөрәҗәгать итеп, кабатланмас характерлар тудырып киткән язучыбыз. Ә кеше характеры – безнең әдәбиятның һәрвакыт иң йомшак ягы булып килде.

Югарыда саналган хәлләрне исәпкә алганда, бүгенге көн язучыларының иҗатын тулы бәяләү турында аваз ачарга да куркыныч иде. Менә әле генә башланган «Әдәби портретлар» сериясе тәнкыйтьчеләрне кузгатып җибәрер шикелле. Дөрес, бу сериягә дә заман үз төсмерен көчләп тагар, хәзерге заман авторлары үзләре хәләл көчләре белән яулаган тулы хаклы урыннарын алып, әдәбият тарихыбызда шул урынnarында ныгып калырлар, дип әйтү кыен. Бүген беренче урынга чыккан Гариф Ахуновның соңга таба бик арткы планга күчү ихтималы бик бар. «Йолдызлар калка»[1] язмасы аның кем булуын да, иҗат дәрәҗәсен дә, кая омтылуын да бик ачык күрсәтте. Гариф бүгенге дәрәҗәсен алсын өчен байтак көч салган кеше буларак әйтәм, әгәр ул бу язмаларын 50 яшенә кадәр чыгарган булса, мин гомергә дә аның юбилей кичәсендә доклад белән чыга торган кеше түгел идем! Үкенүдән файда юк, алдагы көнгә сабак, бер чакта да уртакул талантларга иярмәскә кирәк!..

[1] Г. Ахуновның 1979 елда язылган повесте.

Әле монда килер алдыннан гына, үзем турында язылган һәм басылган тәнкыйть фикерләрен калын бер папкага туплап куйдым. Кызыксынып, кайберләренә күз дә салгаладым.

Флүн Мусин дигән бәндә әүвәл башлап минем иң гади, иң гаепсез, иң эчкерсез «Дүртәү» повестена ташланган икән. (Мәкалә «Казан утлары»нда[1] басылган.) Ул мине әсәрнең геройларына – унөч-ундүрт яшьлек авыл малайларына үз фикеремне көчләп тагуда гаепли. «Авыл балалары алай сөйләшмиләр, алай уйлый белмиләр, язучы аларга үз фикерләрен тага» дип, кискен хөкем чыгара. Хәтеремдә, мин ул рецензияне рәнҗеп, борчылып укыдым. Без Флүн белән танышлар идек, мин Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укыганда, ул аспирантурада иде, һәм мин Мәскәү шәкертеннән яклау, теләктәшлек, аңлый алу, әдәбиятны аңлата алу көтә идем! Наивный чаклар!

Канәгатьсезлегемне расларлык дәрәҗәм дә булмагандыр инде. Матбугат йортының икенче катында очрашкач, Флүнне тәрәзәгә терәп бары бер генә сүз әйтә алдым: «Их, шушы шакшы авызны җимерергә!» – дидем. Авылчарак килеп чыккан инде, авызын җимергәндә дә начар булмас иде булуын. Без этап белән лагерьларга барганда, Свердловск, Петропавловск пересыльный төрмәләрендә бер тоткын майор юл буе Сталинны яклап, аны мактап барган иде. Лагерьда без бергә эләктек. Майорны карцерга дневальный итеп куйдылар. Атна-ун көн уздымы икән, майорның авызын – ике иренен дә кисеп алдылар. Бендеровчылар булгандыр инде, алар шундый кансыз җәзалар бирергә яраталар иде...

Минем үчем шул сүз белән калды, менә, Ходай шаһит, Флүнгә кинә сакламадым, этләшмәдем, өстеннән бер мәртәбә дә жалоба дигән әйберне язмадым!

Ә болай сүзләренә, бәясенә бик рәнҗегән идем. Балалар әдәбияты бездә бик зәгыйфь, бер төрле чак иде. Мин, үземчә, уйлый белә дә торган балаларны язып чыккан идем. Бәлки, мин язган малайлар яшендә чакта Флүн Мусин чын дурак, шыр тиле булгандыр? Шул үз танып белүеннән чыгып кына минем әсәрне таптап узгандыр? Бу фикер яши

---
[1] Мусин Ф. Геройга җитди игътибар // Совет әдәбияты.– 1962. – № 1.– С. 146–149.

торгач, яза торгач кына башка килде. Ә менә мин, минем иптәшләрем унөч-ундүрт яшьтә тирән уйлый белә торган кешеләр иде. Гомумән, мин яшь чагымдагы иптәшләремнең нинди катлаулы образлар булуын хәзеррәк кенә аңлыйм. «Дүртәү» повестен мин яратам. Анда минем алдагы әсәрләремдә күренәчәк кешеләрнең яшьлеге, ялгысы бар. Мин белеп, мин аралашып яшәгән кешеләр бар. Язмышымда зур урын алган, мине баеткан кешеләр бар. «Дүртәү»дә минем авылдашларым, яшьтәшләрем, керәшен малайлары – Әтәч Ибан, Бояр Ибаны һәм Озын Микайла Микулае бар. Әлбәттә, алар берсе дә олы акыл ияләре булып чыкмадылар. Ләкин алар малай чакта беркемгә дә охшамаган, бер-берсенә дә охшамаган тулы шәхесләр иде. Балаларның бер чакта да бер-берсенә охшамавына син игътибар иткәнсеңдер. Балаларда бөек рух яралгысы, иркенлекне, ирекне тулы тоярга омтылу чаткысы, иреккә хуҗа булу омтылышы саклана. Яши-яши тормыш кешеләрне кыса, изә, сыта, баса, үзенә яраклы форманы көчләп бирә, көчләп тага, көчләп үзгәртә. Кешеләр утыз-кырыкларда барысы да бер-берсенә охшый башлыйлар. Тормыш моны кычкырып, аңлатып эшләми, кешеләрне иң нык кысу, үзгәртү юллары иң тын, иң мөһим даирәләрдә эшләнә. Тәнкыйтьтә диктатор булырга җыенган Флүн Мусин балаларның фикер йөртә алуын «Дүртәү» повестенда ук кичермәде, аларны сытып, изеп, бары тик ул теләгәнчә генә, ул рөхсәт иткәнчә генә яшәүләрен, фикер алышуларын теләде. Аннары авторның үзе кадерле дип санаган, үзе яза торган чор кешеләреннән тапкан фикерләрен хәл кадәренчә, логика сыйдырган хәтлесен балаларга да тапшыру ихтыяҗы юкмыни? Әле монда килгәч, кулга эләккән «Советский экран»[1] журналын актарып утырам. (№20, 1980 ел). Анда яшь актер Николай Еременко[2] белән интервью басылган.

[1] 1925–1998 елларда нәшер ителгән, кино сәнгатенә багышланган журнал.

[2] Николай Николаевич Ерёменко-младший (1949–2001) – рус совет театр һәм кино актёры, кинорежиссёр. Ленин комсомолы премиясе лауреаты (1980), РСФСРның атказанган артисты (1983), Россия Федерациясенең халык артисты (1994).

Ул Стендальнең[1] «Кызыл һәм кара»[2] романы буенча куелган фильмда[3] баш рольне – Жюльен Сорельне уйнаган икән. Жерар Филиптан[4] соң! (Мин Ж. Филип уйнаган фильмны[5] гына караган идем.) Шунда Еременконың кызыклы гына бер фикере күземә чалынды. Ул болай ди: «Мне казалось, что раз мне двадцать один год, и я ровесник Жюльену Сорелю, то все получится само собой – ведь я должен его понимать как никто. Это было заблуждением. Весь пародокс образа в том, что Стендаль вложил в этого юношу огромный опыт чувств и мыслей з р е л о г о ч е л о в е к а. (Разрядка моя.– *А.Г.*) Поэтому он и вызывает восхищение, поэтому так неотразим».

Режиссер фикередерме бу, әллә яшь актер үзе шуңа барып ирешкәнме, әмма ул язучының образлар системасының серен аңлау дәрәҗәсенә барып җиткән.

Кызганыч, шуңа охшаганрак фикер, Ф. Мусинның мордасын коридорда очратканда, минем башка да килеп киткән иде, әмма җыеп кына әйтә алмаганмын! Авторның үсмерләргә дә үз тормыш тәҗрибәсен һәм акылын ышанып тапшырырга хакы һәм хокукы барлыгын аңа аңлата алмаганмын. Бала яшәешенең төрлелеген, кеше акылының катлаулы формалары нәкъ менә балачакта яралуын әйтеп Ф. Мусинны ышандыра алмаганмын, әлбәттә! Әгәр минем геройларым да ул чактагы балалар әдәбиятының «батырлары» Җ. Тәрҗеманов[6], Ә. Бикчәнтәева[7] әсәрләрендәге сымак «ту-ту» быр-

---

[1] Мари-Анри Бейль (1783–1842) – француз язучысы, психологик роман жанрына нигез салучы.

[2] Стендальның 1830 елда язылган «Красное и чёрное» романы.

[3] 1976 елда Стендаль романы нигезендә төшерелгән совет нәфис фильмы (режиссёры – С. Герасимов).

[4] Жерар Филипп (1922–1959) – француз театр һәм кино актёры, «Сезар» премиясе лауреаты (1990).

[5] Режиссёр Клода Отан-Лараның 1954 елда Стендальның «Красное и чёрное» романы буенча төшерелгән нәфис фильмы турында сүз бара.

[6] Җәвад Әфтах улы Тәрҗеманов (1920–1995) – язучы, техник фәннәр кандидаты (1965). ТАССРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе (1983).

[7] Әминә Әхмәт кызы Бикчәнтәева (1913–1986) – татар шагыйрәсе, балалар язучысы.

гы кычкыртып, колхоз урамнарында кызыл әләм тотып көл җыеп йөрсәләр, мөгаен, Ф. Мусин да мине мактаган булыр иде. Мәсәлән, ул минем «Берәү» повестен һич тә кабул итә алмады, әллә нинди теоритик һәм әдәби гаепләр табып, еллар буена минем башка чүкеп килде. Повесть русча «Вернись к истоку» исеме белән басылып чыккач[1], ул, борылды да, «автор үз гаебен аңлаган, әсәрнең идея юнәлешенә башка юл биргән» дип, канәгатьләнү белдерде. Тиле! Сантый! Ахмак! «Вернись к истоку» фикере «Берәү» повестеның бөтен барлыгына салынган, һәм Исхакка «возвращаться» итәсе дә юк, ул авылда кала, калачак, гомергә Күктауда яшәячәк кеше. Русчага тәрҗемә иткәндә женский, мужской родлар катлаулылыгы аркасында гына повестьның исеме үзгәрде, аңа карап аның эчтәлеге дә, формасы да, идеясе дә тамчы да үзгәрмәде. Ф. Мусин шул вак кармакка килеп капты, ни йотканын сизми дә калды!

Ф. Мусин мине иҗатымның башыннан ук өнәмичә каршылады.

Мин – әдәбиятка егерменче, егерме икенче съездлардан соң кереп киткән кеше. Мин һәрвакыт кеше рухының иреген яклап җырладым. Сталин чорының тарих күңелендә нинди авыр булып ятканын мин сизә идем, беләидем. Кешеләрнең аңына богау салырга әзер торучылар гомерем буе минем кан дошманнарым булды. Бер урында, вакыт иркенрәк чакта, бу җитди мәсьәләләр әсәрләрдә генә түгел, минем үз язмаларымда, куен дәфтәрләрендә дә тулы чагылыш табарга тиешләр...

Ф. Мусин минем әсәрләр чыкканны, чебешне сагалаган тилгән кебек, саклап кына тора башлады. Ул арада мин аның кемлеген аңлап алдым, егетнең адымы бәләкәй, колачы тар икәнен аермачык күрә башладым. Ләкин мәсьәләнең икенче җитди ягы да бар иде. Безнең җитәкче даирәләрдәге иптәшләр татар әдәбиятын укымыйлар. (Кызганычка каршы, рус һәм дөнья әдәбияты үрнәкләрен дә бик сирәк укыйлар дип беләм мин аларны!) Ә укучы массаның күпче-

[1] Гилязов А. Вернись к истоку // Гилязов А. Диляра. Роман. Авторизованный перевод с татарского В. Анчишкина, Я. Мустафина.– М.: Молодая гвардия, 1973.– С. 49–52.

леге әсәрләргә бәяне әнә шул җитәкче иптәшләр авызыннан ишетеп белә. Безнең укучылар массасында соры төркем өстенлек итә әле. Мин бу турыда кайчандыр «Ә син үзең кем, укучы?»[1] дигән мәкалә дә язып чыккан идем. Ул заманнар байтактан узса да, укучыларның әдәбиятны кабул итү мәсьәләсе һаман шул дәрәҗәдә кала килә. Мәктәпләр, ВУЗлар күпме кешеләрне укытып чыгара торалар, ә язучыларга килгән хатлар һаман бер дәрәҗәдә кала киләләр, дисәң дә ялгыш булмас. Укучылардан килгән хатларның кайберләрен архивка салып куярга да оят. Гомумән, укучы массада бер фикер булдыру язучы эше түгел, ул – тәнкыйтьнең турыдан-туры бурычы. Укучы әсәрне укый, уйлана, ә бәяне радиодан ишетеп, телевидениедән карап тыңлап бирә. Мактыйлар икән, шулай! Хурлыйлар икән – шул кирәк Аяз Гыйләҗевкә! Менә шундый кырыс чынбарлык яшәп килгәндә, эш башында сине өнәмәүчеләр торганда кыен шул! Югары даирәләргә дә, түбән массаларга да фикернең орлыгын һәрвакыт ул сала!..

Минем иҗат актив кына башланды. Теләктәшләр дә бар иде! Академия театрында мине зарыгып көтеп алдылар, бер сезонда ике пьесам куелды. Театр тирәсендә, әдәбият тирәсендә йөрүче эшкуарларны бу факт үзе генә дә җенләндерде! «Ничек? Бер сезонда ике пьеса?! Мондый бәхет К. Тинчуринга да тәтемәгән! Яле, яле, карыйк: нинди фикерләр алып килде икән бу шома егет?!»

Ул чакта нинди бәхәсләр купканын исемә төшерәм дә тәннәрем чымырдап китә. Кемнәр генә, кайларда гына мине каһәрләмәделәр!.. Якларга дигәндә кеше табылмаса да, кыйнарга тотынсалар, халык җиңел күтәрелә бит ул! Дөньяда әдәбият тирәсендә чуалган толпадан да әшәке халык юктыр! Мин моны кат-кат сынадым. Газеталар эт урынына өрделәр, радиолар чинады. «Чаян» журналында карикатура чыкты. Берәү «Җиз кыңгырау»ны[2] кага, халык, колагын тотып, театр тирәсеннән чаба... Көчлесе дә кыйный, көчсезе дә артка китереп тибә. Яралар гына мин бичараны! Менә шундый тукмаулар аша мин театрга килеп кердем. Өмет белән як-ягы-

[1] Әлеге мәкалә «Сайланма әсәрләр»нең 2 нче томына кертелде (Татар. кит. нәшр., 2014.– 2 т.– 106 б.).

[2] А. Гыйләҗевнең 1959–1960 елларда язылган пьесасы.

ма күз салам, өлкәннәргә – драматургларга карыйм. Нәкый Исәнбәт тә сәламәт чак. Театрларга килә, җыелышларда була. Күрә. Мине егып кискәннәрен күрә, дәшми, авызын гына ера! Риза абый[1] дәшсә дә аның тавышын кем ишетә! Әдәбиятта Риза Ишморатның бер чакта да үз тавышы булмады... Нәкый Исәнбәтнең улы Булат Гыйзәтуллинның[2] КПССның өлкә комитеты секретаре чаклары. Исәнбәтнең дәшмәвенә улы сәбәп булдымы әллә, дип тә уйлыйм. Югыйсә, Исәнбәтнең фикере миңа карата уңай иде. Аның да улының юлына киртә куярга омтылышы булмагандыр. Шау-шуда җитәкчеләрнең колак тиз тора бит ул! (Үзенә бер-бер көтелмәгән бәла килмәгәе!) Аның бүресе улаган еллар – Ленин ордены алды, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе булды. Булат Гыйзәтуллин, пьесаны күтәреп, театрга спектакль карарга килгән. Алтынчы рәттә утыра, тезендә пьеса, кулында ручка. Халык кайсы урында, нинди фикерләргә реакция ясый, шуларны билгеләп утыра. Актерларның, театр җитәкчеләренең коты алынды. Булат ашыгыч рәвештә мине үз янына чакырып алды: «Нигә син *халык* та *халык* дип сөйлисең, нигә пьесаңда бер генә дә *партия* дигән сүз юк?!» – дип котымны алды. Афишаларда чыккан 11 спектакльне уйнадылар да, «төзәтергә» дип туктаттылар. «Төзәтергә» дип югарыдан кушып туктатылган спектакльне яңадан сәхнәгә меңгерү өчен я җиде башлы дию, я оятсыз, битсез бульдозер булырга кирәк. Табигый рәвештә спектакль чәнчелеп барып төште. «Җиз кыңгырау» тирәсендә башланган ыгы-зыгылар, язын, «Киек Каз Юлы»[3] спектаклен кушып чәнчелдерде, мине ике уңышсыз пьеса авторы итеп сүгәргә керештеләр...

Ничек яшәлгән диген?

Ничек түзелгән?!

---

[1] Риза Фәхретдин улы Ишморат (Ишморатов, 1903–1995) – драматург. ТАССР (1953) һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1983).

[2] Булат Миңнулла улы Гыйззәтуллин (1920–1989) – 1961–1973 елларда ТАССР мәдәният министры. РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1970).

[3] А. Гыйләҗевнең 1960–1961 елларда язылган пьесасы.

Утызар-кырыгар ел чүп язып бер мәртәбә дә кыйналмаган язучыларыбыз күпме... Ә мине... тукмадылар гына! Хәзер дә янбашлары сызлый...

Ничек исән калынган, дигәндә, Мәскәү коткарды. Мәскәү руслары, Мәскәү яһүдләре аралап калган, алар алга атларга көч биргән, дәрт өстәгән. Беренче куелган «Җиз кыңгырау»ны Мәскәүдән килгән авторитетлы комиссия бик мактады. (Д. Щеглов[1], Габович[2], Вл. Блок[3] һ.б.) Мактау гына түгел, шул пьеса белән мине – әле союз члены да булмаган исемсез кешене – Переделкинога[4] драматурглар семинарына чакырдылар. (Гаҗәп әй, гаҗәп көннәр – электричкага беренче утыру, билетны алдан алмыйча юлда штраф түләү! Беренче тапкыр Мәскәүдә, беренче тапкыр метро, иҗат йорты, беренче тапкыр Мәскәү театрында булу! Вахтангов ис. театрда[5] «Иркутская история»[6]не карадым. Фикер алышуларда москвичлар, руслар әсәрне тетәләр генә, ә мин Ю. Борисованы[7] карап, өч көн сөйләшә алмыйча дулкынланып йөрдем. Хәзер дә шул чактагы тавышы колагымда яңгырап-яңгырап китә. А. Арбузовны[8] укый башласам, күз алдымда М. Ульянов[9]

[1] Дмитрий Алексеевич Щеглов (1898–1963), совет драматургы.

[2] Михаил Маркович Габович (1905–1965) – совет балеты артисты, балетмейстер, педагог, РСФСРның халык артисты (1951), Сталин премияләре лауреаты (1946, 1950).

[3] Владимир Борисович Блок (1918–?) – театр белгече, тәнкыйтьче.

[4] Язучылар иҗат йорты.

[5] 1921 елдан эшләп килә торган Е. Вахтангов исемендәге Дәүләт академия театры.

[6] 1959 елда А. Арбузов пьесасы буенча сәхнәләштерелгән спектакль турында сүз бара.

[7] Юлия Константиновна Борисова (1925–2023) – рус совет театр һәм кино актрисасы, телевидение алып баручысы. СССРның халык артисткасы (1969), Социалистик Хезмәт Герое (1985), РСФСРның һәм Россия Федерациясенең Дәүләт премиясе лауреаты (1969, 1995).

[8] Алексей Николаевич Арбузов (1908–1986) – рус совет драматургы. СССРның Дәүләт премиясе лауреаты (1980).

[9] Михаил Александрович Ульянов (1927–2007) – рус совет театр һәм кино актёры, режиссёр, театр эшлеклесе. СССРның халык артисты (1969), Социалистик хезмәт Герое (1986).

белән Ю. Борисова[1] гына тора!.. Беренче тапкыр Кызыл мәйданга аяк бастым, мавзолей каршысына килдем! Бу хәл 1959 да микән? 1960 елның март-апрель айларында булды – миңа 32 яшь!) Җитәкчеләрем – иң күренекле кешеләр: В. Ф. Пименов, ул чакта «Театр»[2] журналының җаваплы редакторы. В. А. Гольдфельд[3] – күренекле рус драматургы, заманында транспорт театрының баш режиссеры булган кеше. Семинар җитәкчесе – Пистоленко[4], Дәүләт премиясе лауреаты. Мактыйлар мине! Шәп пьеса язгансың, заман рухын тотып алгансың, диләр. Ничек алай? Казанда шушы сүзләр өчен, шушы кешеләр өчен, шушы пьеса өчен татар туганнарым мине эт типкәсендә йөртәләр, ә монда мактыйлар?! Семинардан соң «Театр» журналында минем бәләкәй генә мәкаләм дә басылып чыкты. Куркаклык, изелү, сытылу – юньле олы мәкалә язган булсам да басыла иде. Тик Казан минем котны алып өлгергән иде инде! Шунда мин үземнең яңа пьесам «Киек Каз Юлы» турында сөйләдем... «Зинһар, яз! Син зур драматург!» – диделәр миңа. Авыллык көчле, куркаклык та бар, өркетеп тә бетергәннәр, мин шул чакта үземә булган мөнәсәбәтне файдалана алмадым! Дөрес, «Җиз кыңгырау» пьесасы шундук рус телендә басылып чыкты. «Советская драматургия» альманахында бастылар[5]. Фото белән, биография белән. Кавказ халыклары ул пьесаны куеп та йөрделәр. Музыкасын кемнәргәдер җибәргәнем әле дә хәтеремдә.

---

[1] Владимир Фёдорович Пименов (1925–1995) – әдәбият һәм театр сәнгате белгече, тәнкыйтьче, «Театр» журналының баш редакторы (1960–1964), М. Горький исемендәге Әдәбият институты ректоры (1964–1985). РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1965).

[2] Рус совет драматургиясе, театр, театр тәнкыйте турындагы журнал.

[3] Владимир Александрович Гольдфельд (1908–1982) – театр режиссёры һәм драматург. РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1954).

[4] Владимир Иванович Пистоленко (1908–1973) – рус язучысы.

[5] Кара: Гилязов А. Медные колокольчики / драма в трёх действиях, четырёх картинах / пер. с татар. Вл. Гольдфельда // Современная драматургия.– Кн. 20.– Москва, 1961.– С. 71–108.

Шул язда, әйткәнемчә, академия театры[1] «Киек Каз Юлы»н сәхнәләштерде. Баш рольдә СССРның халык артисты, табигый таланты чиксез булган Хәлил ага Әбҗәлилов[2] иде. Режиссерым Ш. Сарымсаков[3] пьесаны аңламады, жанрны дөрес билгеләмәде, минем тәҗрибәм юк, сүземне сүз итә алмыйм, спектакль сыек булып чыкты.

Әмма шул ике пьесадан Хәлил ага мине яратып калды. Авырып больницага кергәч, мин аның янына бардым. Чиксез сөенде! «Бу пьесада Шекспир югарылыгында торырлык фикерләр бар», – дигәне хәтердә. «Яланаяк чыккач кына урамда күпме пыяла ватыклары ятканын күрәсең» һ.б. җөмләләрне ул бик нык куәтләгән иде...

Мине «Театр» журналына чакырып алдылар. ««Киек Каз Юлы» пьесасы искиткеч зур фикергә ия, без аны бастырып чыгарырга планлаштырдык, тәрҗемәче белән эшкә утырыгыз», – диделәр.

Киттем. Тәрҗемәчем Я. М. Апушкин[4] белән очраштык. Ул бер пәрдәлек кыска пьесалар остасы икән, белемле, гадел, эрудит. Тик минем пьесаны ул аңлап бетермәде, тәҗрибәм юк, акыл да азрак, үз сүземне үткәрә алмадым (Казанда алган җәрәхәтләр каный, каный!), бу тәрҗемәче белән килешмим, дидем дә... кайтып киттем. Шәүкәт Галиев янында торам, ул ВЛКда укый, аның иманы да бик гади: «Безнең халык – зур халык, безне үз телебездә укысалар да җиткән!». Ул шундый акыл бирде, ул иман миндә байтак елларга кадәр яшәп килде. Нинди акылсызлык! Тәкәббер һәм буш татарлар шул без!

---

[1] Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры.

[2] Хәлил Гали улы Әбҗәлилов (1896–1963) – Г. Камал исемендәге театр артисты. СССРның халык артисты (1957), Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1958).

[3] Ширияздан Мөхәммәтҗан улы Сарымсаков (1911–1999) – режиссёр, актёр, педагог. ТАССРның (1945) һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1957). ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1958).

[4] Яков Владимирович Апушкин (1898–1989) – рус язучысы, тәрҗемәче.

Качалов театрының[1] ул чактагы баш режиссеры Е. А. Простов[2] мине үзенә чакыртып алды. Грипп белән ятам, температурам кырык чамасы, киттем, күңел изгелек көтә, күңел теләктәшлек, аңлашу эзли. «Киек Каз Юлы»н укыган. Кочагын җәеп каршылады. «Минем фамилиям генә Простов, үзем алай беркатлы кеше түгел», – дип, шаяртып куйды. «Татар драматургиясен күзәтеп барабыз, күренекле даталарга багышлап әсәрләр дә куйгалыйбыз. Мәгәр хәзерге заман темасына язылган заман югарылыгында пьеса юк иде. Син «золотая жила»га юлыккансың. Куябыз!» – дип, мине канатландырып чыгарды. Атылып өйгә кайттым.

Простов дигәнем дә Трусов булып чыкты, режиссерларның колак сак, ишеткән Казан хәбәрләрен, пьесадан баш тартты. (Авыр туфрагы җиңел булсын мәрхүмнең, бик кыен чакта азга гына булса да дәртләндереп алганы өчен, мин аңа гомер буе рәхмәт укыдым.)

Казанда да яклаучылар, иҗади ялкын өстәп торучылар булды. Режиссер Габдулла абый Юсупов «Көзге ачы җилләрдә»не[3] сәхнәләштерде. Әйбәт куйды, аңлап, белеп, яратып. Уңыш белән барды, тамашачы аны нык яратты. Һәр очрашканда ул миңа акыл бирә килде, юк-барларга баш бирмәскә өйрәтте. Габдулла абыйның сәнгатьтән, әдәбияттан башка тормышы юк иде. Мин аңа үземнең «Урталыкта» исемле повестемны багышладым. Соңгы әсәрем «Җомга көн, кич белән...»дә дә аның исемен хөрмәт белән искә алдым...

Бер тапкыр, «Казан» ресторанында Ә. Еники, А. Расих, Н. Исәнбәт, Празат Исәнбәт һәм мин бергә утырганда, Празат: «Менә сез – Ә. Еники, Аяз Гыйләҗев, Н. Исәнбәт – әдәбиятның өч бөркете», – дип безне атады. Их, шул сүзне берәр җирдә, халык алдында чыгып әйткән булсачы!.. Празат ул вакытта исемле кеше иде, терәге дә булды...

---

[1] В. Качалов исемендәге Казан Зур драма театры.

[2] Евгений Александрович Простов (1900–1969) – театр режиссёры. ТАССРның (1948) һәм РСФСРның (1950) атказанган сәнгать эшлеклесе.

[3] А. Гыйләҗевнең 1961 елда язылган пьесасы.

Хәлләр, өстән-өстән генә әйткәндә, менә шулай башланып китте. Минем драматургиядәге «фокус»лар бетеп тә җитмәде, «Өч аршын җир» повесте дөньяга чыкты...

Бәхәс «Лит. Газета»га кадәр барып җитте. Повестьның башын бетерүгә байтак кеше катнашты. Җитәкче даирәләр үзләренә «яшерен ышанычлылар», «яшерен киңәшчеләр» әдәбият тирәсендә тамак туйдыручылар арасыннан таба тордылар. Шул арада аларның миңа биргән бәяләре Югары йортка да барып иреште. Партиянең өлкә конференциясендә Ф. Табеев[1] повестьны бик каты гаепләп чыкты. Комсомолның өлкә комитеты беренче секретары Р. К. Беляев[2] тә повестька тибеп узды. (Байтак еллар узгач, Рәис Кыямович ул эштән киткәч, мин аннан: «Нигә алай эшләдегез?» – дип сорадым. Ул: «Кем барын да укып, тикшереп өлгергән инде, ни язып бирәләр, шуны укыйсың!» – дип икърар итте.) (Җитәкче даирәләрнең «әдәби эшчәнлеге» турында Ф.М[3]. миңа шәхсән үзе ике тапкыр серне чиште. Беренчесе, Тукай клубында утырганда, икенчесе Апаста әдәби атналык уздырырга баргач. «Һе, Табеев өчен бөтен мәкаләләрне мин язам, күбесен укып та тормый, кул куя да җибәрә», – дип мактанды).

Болай да иҗат аксаган чак. Икеләнгән, каушаган чагым! Алты кешелек гаиләне тотарга кирәк! Бөгелеп үк бетмәсәң дә, сыгылып төшәсе дә килми! Каушый-каушый «Зәй энҗеләре»н яздым. «Инде монысына тел тидермәсеннәр иде!» дип курка-курка, «Шомырт чәчәк атканда»[4]ны Күчмә театрда куйдырдым...

Ничек яшәлгән? Ничек түзелгән?!

«Дружба народов» журналыда повестьны бүләкләү турындагы карар чыкканда, мин Ялтада драматурглар семинарында идем. Бөтен семинарның, җитәкчеләрнең, Н. Громовның[5],

---

[1] Фикрәт Әхмәтҗан улы Табиев (1928–2015) – партия һәм дәүләт эшлеклесе, дипломат. 1960–1979 елларда КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре.

[2] Рәис Кыям улы Беляев (1935–1996) – партия һәм хакимият хезмәткәре. РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1995).

[3] Флүн Мусин турында сүз бара.

[4] А. Гыйләҗевнең 1967 елда язылган пьесасы.

[5] Николай Иванович Громов – әдәбият белгече.

Л. Зоринның[1] һәм башкаларның миңа мөнәсәбәте бик нык үзгәрде...

«Знамя» журналында «Өч аршын җир»не «Күтәрелгән чирәм»нәр[2] рәтеннән биш-алты повесть арасында күтәреп чыкканда, мин Кисловодскида санаторийда идем...

Казан мине һаман тәпәләде.

«Өч аршын җир»не нәшриятка биреп карыйм. Юк, чыгармыйлар, тетәләр мине «идеологиягә каршы эш йөртә» дип.

Моннан ел чамасы элек М. Әмир минем белән бик ачылып сөйләшеп йөри башлады. Мин аның балачак повестьларын йомшаклыкта гаепләп сөйләшкәчрәк булды бугай бу хәл. «Өч аршын җир»нең басылып чыкмавын ишеткәч, ул: «Ул әсәрне егып ташлауда минем дә катнашым булды инде», — дип уфтанды. Мин аннан, «Әйдә, соң булса да, уң булсын, хәзер чыгарыйк. Үзем сүз башы язам», — дип әйтерме, дип көтәм. Әйтми... Мирсәй агай, заманында искиткеч талантлы дебют ясаган зирәк кеше, гомере буе бер чир белән — «уңай герой» теориясе белән интекте, һәм шул чир аның иҗатын әллә кайчан үтерде дә инде. «Агыйдел»дән соң бер әсәр дә яза алмады мәрхүмкәй. (Авыр туфрагы җиңел булсын!) Утыз җиденче елда нык куркытылган булуы иҗатына зур зыян салды шул.

Хәзер уйлап-уйлап карыйм да, мондый сөземтәләргә киләм: рус халкының, рус интеллигентларының бер-берсенә, әдәбиятларына, чит әдәбиятларга мөнәсәбәте бөтенләй башкача — киңрәк, демократичныйрак. Бездә күремсезлек, тарлык өстенлек алып киткән. Дөрес, мин бар кешеләрнең дә мине аңлауларын, миңа теләктәшлек күрсәтүләрен көтмим, өметләнмим дә. Әмма минем бер сүз көтеп, күз текәп торган кешеләрем бар иде. Беренчесе, кабатлап әйтәм, Нәкый Исәнбәт. Мин гомерем буе аңа карадым. «Сезгә алмашка килә торган талантлы кешене ник бер мәртәбә булса да яклап чыкмадыгыз?!» — дип өзгәләндем. Гомер буе бер сүз дә дәшмәде! Холкы шулай дисәм, Роза Хафизованы Союзга

---

[1] Леонид Генрихович Зорин (1924–2020) — рус язучысы, тәрҗемәче.

[2] М. Шолоховның 1932, 1958 елларда язылган «Поднятая целина» романы.

алдырырга теләп яшь юргатай шикелле чабып йөрде, Сибгат абыйга шалтыратты, Ахунны ничә мәртәбә сүгеп китте. Егәрле, каһәр, кирәк чакта йөри дә беләǃ..

Кайчандыр мин Фатих Хөснидән җылы сүз көтә идем.

Башта минем белән уртак фикерле кебек тоелды да, соңра, «Урталыкта» повесте басылгач шундый фикерләр язып чыкты, әгәр 37 нче ел булса, мине шылт та иттермичә чыгарып аталар иде. Аннан да соңра... миңа Ф. Хөсни сүзенең әһәмияте бөтенләй калмаган иде...

Рәхмәт! Гази ага Кашшаф миңа игътибарлы гына булды.

Чордашлар, яшьтәшләр үзара җылы сүзләрен җәлләмәделәр... Яшәлде... Ф. Миңнуллин да, Г. Ахунов та җылы-җылы гына сүзләр әйткәләделәр. Ләкин алар һәммәсе дә минем иҗатны өзәләр иде... Ә иҗат, башта ук искәрткәнемчә, өзек-өзекләрдән тормый, һәр язылган юл – минеке! Һәр әйтелгән сүз – минеке! Бары тик шуларның һәммәсен җыеп караганда гына язучыны азмы-күпме ачып буладыр...

Инде ул турыда да уйланылмый иде.

Инде яралар төзәлеп, әрнүләр онытыла башлаган иде. Инде «нинди шәп әсәр язсам да барыбер тиешле бәяне алачак түгелмен!» дип уйлый идем. Р. Мостафин әле монда китәр алдыннан гына: «Менә синең әсәрләргә бәяне үз вакытында куеп өлгерә алмадык шул. «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят»ең Ч. Айтматовның «Ранние журавли»[1]ыннан бер дә ким түгел», – дип сөйләп торды. Татарныкы төштән соң?! Мин үзем дә әсәремнең нинди югарылыкка ия булганнын беләм, сизәм, чамалыйм, тик хәзер аннан ни файда?!

«Онытыла башлаган иде» дип тә бераз ялганлыйм бугай.

Хәтер ул – хәрәкәтләр иле. Хәтергә сеңеп калган бер генә олы факт та күңелдә тик ятмый, авыр яки җиңел минутларда, шатлыкларда, газапларда – ә иҗат бары тик шатлык, яисә газап аша гына туа да – хәтергә сеңеп калган... усаллар һаман үз эшләрен эшлиләр – изәләр, сыталар, кечерәйтәләр!

Һәм шул чакта, инде өметләр киселгәндә, яңа буын тәнкыйтьчеләре килеп чыга. Яңа буын өчен «искеләр» таләп иткән дөреслекләр көлке, алар яклаган иҗат принциплары ялган булып чыга. Хәтта алар үзләре үк, күңелләре белән си-

[1] Ч. Айтматовның 1975 елда язылган повесте.

зеп, чак-чак кына көрәш кырыннан ерагаялар, тактикаларын гына түгел, стратегияләрен дә үзгәртәләр...

Әгәр мин моннан җиде-сигез ел уйланган «Җомга көн, кич белән...»не 79 нчы елда гына иҗат иткәнмен икән, монда яңа буын тәнкыйтьчеләренең дә өлеше зур. Чөнки хәтердә өстенлек алган кыйналуларны җиңеп, күңелгә хөрлек, ирkенлек тою тойгылары да инде...

Шуннан инде мин төп уйлануларымны яза башласам да буладыр.

Мин бу юлларны 1 ноябрьдә башлаган идем, 7 нче биткә җиткәч туктадым, кул бик сызлады. Бик нык! Аннары бәйрәм арасында башка мәшәкатьләр чыгып торды. Ригадагы дусларым – кунаклар килеп төште, алар белән әвәрә булдым, кунакларны озаткач, тагын бер-ике көн эленке-салынкы йөрдем. Бүген инде 9 ноябрь. Якшәмбе көн. Хәзер көндезге сәгать бер. Кыеклап-кыеклап, бурый-бурый кар ява. Һава үзгәрәсен кичә дә сиздем, көне буе йөрәк авыртты. Сәбәпсез авыртмый ул йөрәк. Һава үзгәрәсен белмәдем, «нигә сызлый соң бу йөрәк?» дип уйлап-газапланып кичәге көнне үткәрдем. Сәбәбен белгәч, җиңеләеп китәсең.

Мин бит «Җомга көн, кич белән...» повестена «Соц. Татарстан» газетасында оеша язып калган заговор турында гына язмакчы идем... Ә уйлар кайларга алып китмәде.

Өйдә чакта мин «әйдә, чыкса да исем китми!» диебрәк ирәеп утырган идем. Соңыннанрак кына: «Юк, тәнкыйть мәкаләсе чыкса күңелсез буласы икән!» дип төзәттем...

Юлда да, монда да бик ул турыда уйландым.

Повестьның шәплегендә шигем юк! Күңелем кебек керсез әсәр! Нигә соң шушы әсәргә дә Рафаил Төхфәтуллин, Рабфак Тимергалин[1] һәм Миргалим Харислар[2] теш кайрый?! Хәтта: «Мәкалә М. Мусин[3] белән килешенгән» дип алдауга

---

[1] 1980 елларда «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан») газетасында эшләгән журналист.

[2] Миргалим Харис улы Харисов (1939–2009) – 1967 елдан «Социалистик Татарстан» газетасында әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире.

[3] Мөдәррис Муса улы Мусин (1923–1994) – 1969–1984 елларда КПССның Татарстан өлкә комитетында мәдәният бүлеге мөдире

кадәр барып җитәләр! Алдауга барып җитү факты мине бик нык сагайтты. Димәк, бу – чыннан да заговор булган.

Р. Төхфәтуллин...

«Двенадцать разгневанных мужчин»[1] дигән гүзәл картинада сукыр бер карчык «малай, чыннан да этисен үтерүче» дип ялган шаһитлык итә. Присяжныйларның берсе, исеме онытылган, ул рольне атаклы Генри Фонда[2] башкара, карчыкның ялган гуаһлыгына мондыйрак бәя бирә: «Беркем тарафыннан кадерләнми торган, бөтен кеше игътибарыннан читтә калган ялгыз карчык. Язмыш тарафыннан каргалган, кешелек тарафыннан кимсетелгән җан... Ә монда кинәт кенә аңа игътибар итәләр! Фотографлар чаба, тирәсендә корреспондентлар әйләнә... карчык кинәт зур фигурага әверелә! Аңа бу роль ошый, ул яңадан-яңа детальләр уйлап чыгара. Аңа шушы вакыйгада катнашу һәм кирәкле кеше ролен уйнау бик ошый. Ул аңа бик тансык!» – ди.

Әлбәттә, кино әллә кайчан каралган, киносценарийны укыганга да әллә кайчан, текстны бутыймдыр да, әмма образның логикасы өчен кулымны кисәргә бирәм, шулай иде.

Р. Төхфәтуллин...

Дөрес, көнләшү дә бардыр. Мин туктаусыз язам, аның ун еллар буена бер генә яңа әсәре дә күренми. Ләкин, иң мөһиме, иң дөрес аңлату – әнә югарыдагыча: хәзер ул беркемгә дә кирәкми, беркем дә аның белән исәпләшми, беркем алдында да кадере юк, һәм кинәт Аяз Гыйләҗевне эләктерергә җай чыга. Бүре турындагы фәлсәфәсе аның комга корылган. Ул, Әлмәттә очраганда, миңа аны аңлатып маташты, минем элекке әсәрләрдән нидер алып, параллель үткәреп, мине бүре характерлары җырчысы итеп күрергә теләде бугай. Ләкин мин бик күптәннән инде Рафаил Төхфәтуллин дигән язучыны белмим, мин исерекбашны гына беләм, пычрак балаклы, шакшы киемле, әчегән кәбестә исе аңкып торган берәүне генә күреп беләм. Бөтенләй онытылып барганда кинәт аңа игътибар көчәя, редактор урынбасары үзе сөйләшә, кул бирә!

---

булып эшләгән.

[1] Драма (реж. Сидни Люмет, 1957).

[2] Генри Джейнс Фонда (1905–1982) – күренекле Америка актеры, «Оскар» премиясе лауреаты.

Бүлек мөдире аны дәртләндерә! «Яз» дип кулына каләм тоттыра. Ә газетада күренәсе килә Рафаилнең, байтак еллар әдәбиятны үз кулында тотып торган авторны салып-салып тукмыйсы килә аның...

Һәм газетага, сөенә-сөенә, мәкаләсен илтә...

Мин бары тик шулай гына уйлыйм: бу мәкалә – аның көчсезлеге. Бу мәкалә – аның үз-үзенә ясин чыгуы...

Инде Р. Тимергалинга килик. Бик озак баш ваттым. Ә баш ватып торырга да кирәк булмаган! Французлар мондый очракта ни диләр әле, «ищите женщину!» диләрме? Французчасы хәтердә калмаган, егетләрдән шалтыратып сорадым, шагыйрь башлары[1] белән шуны да белмиләр! Женщину надо искать, друг мой, и не более!..

Миргалим Харисов исә Рабфакның күләгәсе инде!.. Минем аларга ачуым да килми. Хәтта Тимергалинга да үпкәләмим! Ул да үзенчә рыцарь булырга теләгән бит!..

Хатын-кыздан сак булырга кирәк!

Отеллоның хатын-кызларга биргән бәһасе байтак очракта гадел булып чыкканын тормыш күрсәтте инде! Эш арасына, сер уртасына бер чакта да хатын-кызны кертергә ярамый... Бары тик шул гына...

Мансур Валеевләр буыны тәнкыйтьчеләр әдәбиятта яхшылыклар гына күтәрергә тиеш дип беләм. Абсолют дөреслеккә, хакыйкатькә ирешү – мөмкин булмаган хәл, әмма без бергәләп җирдәге хаклык өчен көрәшергә бурычлы!

Мин шулай уйлыйм.

Һәм шулай уйлый алуыма сөенәм!

Сөенә алу да олы бер бәхет бит ул!

*АЯЗ. 12 ноябрь, 1980 ел*

*Рига–Дубулты*

---

[1] Күрше бүлмәдә Роберт Миңнуллин белән Рәдиф Гаташ яшәве турында сүз бара. – *Н. Гыйләҗева искәрмәсе.*

# Кәкре агачтан туры күләгә төшми…[1]

21 март, 1986 ел

Рига–Дубулты

Ә мин үткәннәремдә караңгы сукмаклар калуын теләмим, ялгышлар болай да күп, хаталар мул, заманның койрыгына ябышырга теләп атаказга сәлам биргән чаклар бар, дуңгызга да «җизни!» дип бил бөккән чаклар булгалады. Бу җәһәттән исә йөземнең ак калуын телим…

Мин башкорт белән татар низагын беренче мәртәбә Фатих Хөснинең 50 еллыгында «Казан» ресторанында, шуның кечкенә бүлмәсендәге банкетта ишетеп калдым. Әле мин – әдәбият тирәсендә йөри генә башлаган кеше, лагерьдан кайтып яңа аралаша башлаган яшь язучы, шулай да, ничектер, банкетка эләктем. Башкортлардан Кадыйр Даян бар иде.

Сүзенең башы, йомгагының очы онытылган, халык шактый кызып, бер-берсен ишетми башлаганда, уртага бәхәс калкып чыкты. «Башкорт белән татар пычакка-пычак яши башлаганнар икән, моңа сәбәпче бары тик казанлылар!» – дип кызды Кадыйр Даян, ә безнекеләр тыйнак кына аңа каршы төшеп азапландылар.

1958 ел иде бу.

Мин лагерь юлларында күргән бердәнбер башкорт – юаш кына, сары чәчле, ак керфекле Әхмәян Дәминдаров иде. Башкорт идеме икән, Башкортстаннан гына булдымы, мәгәр ул шул якныкы иде. Ни сөйләшкәнбездер, белмим, сүз булмыйча калмагандыр, мин аңа якын туганыма карагандай карадым. Ач иде мескен, янына аз-маз ризык күтәреп кергәнем дә исемдә, сирәгрәк очлы тешләрен ипи телеменә батырганы әле дә күз алдымда, ә лагерьда ул елларда кыямәт: милләтләр бер-берсе белән сугыша, пычакка-пычак килә, лагерьның яртысы бандеровчылар, яшьләр – әлерәк кенә урманнардан, кайнар кан исен иснәп килгән ярсулар, русларны сөймиләр, арадагы блатнойларны гафу итмиләр, тәртипне үзләренчә урнаштырырга тырышалар. Ә тәртипнең асылы бик гади: ашханәгә һәм хлеборезкага кем хуҗа – шул

---

[1] Аяз Гыйләҗев. Кәкре агачтан туры күләгә төшми // «Таһир Зөһрә».– 2001.– №23(79). 1 декабрь.– Б.4.

лагерьда бай, аз-маз җиңелрәк яши ала... Бүген бандеровчы украинлылар чеченны яки русны үтерә, иртәгә бөтен лагерь җыйнаулашып сугыша. Без — работягалар, нараларга кереп посабыз. Менә баракка ун, егерме, утыз коралланган егетләр атылып керә: кулда — ялтыр-йолтыр пычаклар, «сидеть! сидеть!» дип акыралар тегеләр. Кем кыймшанып карасын, җан үкчәгә тәгәрәгән, кот боттан аскарак төшкән... Кемне эзли алар, шайтан белсен...

Лагерь милли төркемнәргә теткәләнеп беткән: руслар «караларга» сыена, «каралар» — грузин, казакъ, үзбәк һ.б. Төркиләр русларга тартыла, бердәм булганда көч аларда. Украиннар ишле, яшь, көчле, берләшкән, сугышның ни икәнен яхшы белә. Берзаман литвалылар калкып чыкты. Алар да яшьләр, әлерәк кенә «яшелләр» арасыннан урманнардан чыккан, күпме кеше җанын кыйган «сугышчылар». Алар да өстенлек таләп итә, башта русларга каршы чыктылар, торабара украиннар белән аралары бозылды...

1958 ел. Минем шушы көрәш мәйданыннан кайтканга әле нибарысы өч ел. Хатирәләр яңа, яралар яңа, уйлар бер, нигә алай? Кем өчен кырылды лагерьдагы халык?!

Кайтсам, татар язучысының илле еллыгында, банкетта шушы мәсьәлә туып, калкып чыгып, чак кына сугышмый калдык... Мин лагерьда милли чуалышлардан, үзара ыгы-зыгылардан читтә кала алдым. Алардан өстен булдым, бер якка да каерылмадым, дусларны яхшы күңелле интеллигентлар арасыннан сайлап алдым. Берзаман, көндез бик каты сугыш булып, байтак корбаннарның каны җирдә чакта, Актас лагерыннан бөтен «каралар»ны җыеп, этапка алып киттеләр. Мин ул чакта күренмәс кеше идем инде — пресс цехында бригадир, анда да мин этапка иярмәдем, бик нык курыксам да китмәдем, яманат тагып башка урынга барып керәсем килмәде, калдым. Иң гаҗәбе: лагерьдагы биш татарның бишесе дә китмәгән булып чыкты...

Шул көннән, башкорт-татар арасының яңа, сикәлтәле, файдасыз, хурлыклы юлга кереп киткәнен белә-белгәннән бирле мин гел баш ватам: нигә? Ни өчен? Аның безгә түгел, кемгәдер кулай икәнен аңлыйм, лагерьда да КГБ вәкиле русларны чакырып: «Нишләп әле украиннарга баш биреп

торасыз?» – дип котырта икән. Ә украиннарны дәшеп бүтән киңәш бирә... Аңлашыла...

Үсә-үсә агачлар ник кәкрәя дисең син?..

Җавабы бик гади – ул кояшка тартыла, аның да кояш назын күрәсе килә, ә аңа нур бирмиләр, я бер агач комачаулый, я икенчесе... ә аңа үсәргә кирәк, калкырга, ул анда сузыла, монда үрелеп карый һәм кәүсәсе кәкрәя башлаганын сизми дә кала.

Кәкре агачтан туры күләгә төшми, бу – бер. Икенчедән, ярый ла ул үз кояшын тапса, үзенекен!.. Үз кояшыңны тапмыйсың икән, син җиреңә хыянәт итәсең...

**«Егерме елдан соң татарның исеме дә булмаячак»**

Әдәбият-сәнгать күге айсыз, йә кояшсыз була алмый. Ай яки кояш булмаса, адәм баласы күккә үрелеп карамый да, дип беләм. Караса да, чуарлыктан башка берни күрми, йолдызларны исемләп аермый. Әдәбият та– тоташ чуар күк ул, аны җанлы итәр өчен, аңа исемнәр – ай-кояшлар кирәк. Чыңгыз Айтматов дибез икән, бу исем һәркемгә мәгълүм. Ул барында кыргызның күге – күк, гади укучы кыргыз әдәбияты тоташ шундый югарылыкта дип ышана. Әгәр әдәбиятта шундый югарылыктагы лидер юк икән, әдәбият гел талантлардан гына торса да, гади укучы аны бер чакта да санламый. Безгә дә шундый лидер кирәк иде. Үзебезнең әдәбиятның данын читләргә алып чыгарлык Тулы вәкаләтле әдәбият илчесе кирәк иде. Кем ул?.. Бу уй мине менә чирек гасыр инде борчый, тетрәтә. Элегрәк, әллә Ибраһим Газимы ул дип уйладым (яшьрәк чакта!) Түгел – әүлия, пәйгамбәр, җиде кат үлчи торган сак кеше. Мирсәй Әмир дә шундый – куркакөркәк, утыз җидедә сырт сөяге сынганнан соң «уңай герой» дип саташкан, салкын суны да өреп кабучыга әйләндерелгән кеше. Хәсән Туфанмы?.. Чынлыкны бер чакта да аңламый торган наив кеше. Бәшировтан, Сибгат агадан да андый кешеләр чыкмады. Ни кызганыч! Шушы әдипләребезне бер заман Табеев чакырып ала да: «Әй, сез! Нәрсә анда «татар да татар!» дип кыбырсып йөргән буласыз? Егерме елдан соң татарның исеме дә булмаячак бит!» – дип, тегеләрне пыр туздыра! (Кемнәрдер «егерме елдан тулы коммунизм булачак!»

дип лаф орган еллар иде бу!) Моны Сибгат ага үзе сөйләде. Һәм беркем, кыеп, сүз әйтә алмый. Болардан лидерны көтеп буламы?! Лидерсыз гаскәр сарык көтүенә әйләнә, ә язучылар гаскәр түгелме? Шул вакытта мин, нигәдер, Мостай турында уйладым.

Дәрәҗәсе бар, күтәрелгән һәм күтәреләчәк. Кояш ук булмаса да тулган ай дип әйтерлек. Хәйләкәрлеге бар. Биографиясе менә дигән. Дус-иш күп, Рәсүл Гамзатовлар белән бер мафиядә, җитмәсә, саф татар! Беләм, башкорттан татарга тулы борылыш ясамаса да, нигә үз милләтен бөтенләй үк читкә кагар икән?!

Үзе татар әдәбиятын бераз кайгыртып, мафиясе белән, бездә үсеп, калкып чыгарга тиешле кандидатны канаты астына алса?.. Мостай белән минем ара танышлыкның беренче көненнән үк «ялгыш» юлга кереп китте. Мин аның «Айгөл иле» пьесасын тамчы да яратмадым. «Тартай теленнән табар», мөнәсәбәтемне «Урамнар артында яшел болын»да кистереп әйтеп тә бирдем. Әлбәттә, моны Мостайга җиткергәннәр, очрашканда беренче сүзе итеп, «Доносның шундый формасы да бар икән!» дип куйды...

Димәк, мәсьәлә катлаулы, миңа турыдан-туры Мостайга чыгарга ярамый! Мостай «шестеркасы»ның иң ышанычлы әһелләре Габдулла Әхмәтшин[1] һәм Рафаил Сафин[2] белән хат алыша башладым. Нидән башлангандыр, хәзер истә юк, әмма шактый озын, шактый «маҗаралы» хатлар язып, мин Мостайның дипломатиясенә сокландым, мактадым да. (Ансыз булмагандыр инде!) Аны «төрки-татар дөньясының лидеры итеп» тануымны белдердем. Беләм, төз аттым, алдагы очрашуда ул, ирен чите белән генә елмаеп: «Синең миңа карашың үзгәргән икән, рәхмәт», – диде. Шунда мин кыюланып: «Нигә татар түгел соң? Нигә татар булып китмәде-

[1] Габдулла Габдрахман улы Әхмәтшин (1921–1984) – язучы, драматург, журналист, тәрҗемәче. Башкортстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1981)

[2] Рафаил Әхмәтсафа улы Сафин (1932–2002) – башкорт драматургы, шагыйрь, 1974–1983 елларда БАССРның Язучылар союзы рәисе урынбасары. БАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1982).

гез?» – дип сорадым. Ул бераз кыенсынып торды да: «Шулай инде, шулай башланган – шулай бара», – дип куйды. «Нигә татарларга ярдәмгә килмисез? Безгә бик кыен бит!» – дидем. Дәшмәде, көлде генә. Мостай көлә белә!

Бу соравыма җавапны былтыр (ягъни 1985 елда) Пицундада Әмирхан ага Еникидән ишеттем. Мостай Әмирхан агага туп-туры әйткән: «Әгәр мин татар булып киткән булсам, бу дәрәҗәләрнең берсенә дә ирешми идем»,– дигән. Кызганыч!

Халык – милләт!..

### Солы салыгыз аңа, башак болгатыгыз

Татар милләтенең вәкилләре бүген җиде миллионмы?

Милли тамырлар һәрвакыт сугаруга мохтаҗ. Мәсәлән, белоруслар көнбатышта яшәгәндә – поляк, көнчыгышта яшәгәндә урыс булып исәпләнде.

Башкортлар – автономияне беренче булып алган халык. Злобинның[1] «Салават Юлаев»[2] романы. Безнең андый рухтагы роман булдымы?..

Моннан өч ел элек, көздә, делегация составында мин саф татар районы Кушнаренкода булдым, шунда, мәктәпләрдә очрашканда, татар теле укытучылары, башта кыюсызланып, сөйләшә торгач ачылып китеп: «Мәктәпләрдә татар теле кабинетларын «башкорт теле һәм әдәбияты кабинетлары»на әйләндерделәр, дәресләрдә хәзер Мостайны гына укыттыралар»,– диделәр. Ни кызганыч!

Димәк, минем лидер эзләү эшчәнлегем дә пыран-заран килеп, хурлыклы рәвештә тәмамланды...

Яшим, эшлим, язам, уйланам, борчылам. Һаман лидер эзлим. Ансыз булмый, кемдер әдәбиятның байракчысы булырга тиеш. Шул кеше аша халык вәкилләре әдәбиятны бәяли. Шул көнне күз карашы төбәлгән җирдән үзенә йолдыз таба... Андый кеше кем?.. Равил Фәйзуллинмы? «Ул булыр!» дип өметләнгән чакларым да булды. Ун ел мин аңа якын булдым, шул ун ел эчендә ул миннән байтак нәрсә алгандыр дип беләм. (Кайчан исә бер, инде узганнарына әйләнеп карар чак

---

[1] Степан Павлович Злобин (1903–1965) – рус совет язучысы, педагог, Сталин премиясе лауреаты.

[2] С. П. Злобинның 1929 елда язылган романы.

җиткәч, Равил ул елларны телгә алмый калмас!) Югыйсә, ул егеттә талант та, кыюлык та, кайнарлык та бар!..

Инде Туфанмы[1]?.. Белмим...

Эшлим, яшим, тырышам...

Үткәннәргә кайтып күз салсам, уйлана башласам, башым кайный башлый. 60 нчы елларда Академия театрында «Киек Каз Юлы» куела башлады. Биш-алты спектакльдән соң чәнчелдерделәр. «Өч аршын җир» пьесасына академиядә репетицияләр башлануга, Мусин[2] туктатты. Качалов театрында «Один потерянный день» куела башлады. Валиев чакырып алып, өч сәгать буена анасын-атасын, гүр такталарын кузгатып сүкте. «Мәскәүлеләр мактады, министр урынбасары Зайцев хуплады»,– дигәч, «Телисеңме, мин синең үз алдыңда шалтыратам, аның фикере үзгәрәчәк!» – дип мыскыллады... Станиславский исемендәге Мәскәү театрында «Өч аршын җир»гә репетицияләр башлангач, Мусин шалтыратып: «Үзәктән торып безнең эшчәнлеккә каршы чыгасыз, безнең авторитетны бик нык какшатасыз»,– дигәч, нәтиҗәдә, төзелгән договорны юкка чыгардылар... Бер караганда – алар вак-төяк, ә җыела торгач, таулар өелә. Тау күкрәккә ята, изә, сыта... Әйтик, бик гади вакыйга: Казанда өлкә партконференциясе ачыла. Гөнаһ шомлыгына каршы, шул көннәргә минем спектакль – «Хушыгыз, тургайлар!» билгеләнгән. Мусин театрга боера: «Мондый тантаналы көннәрдә Аяз пьесасы куелырга тиеш түгел!». Әлмәт театры Мәскәүгә отчет белән барырга җыена – театр атналыгы. Арада минем «Әгәр бик сагынсаң» да бар, театр әле берни белми, декорацияләр алып бара, әзерләнә, ә Мусин Ирна Гатинага кисәтеп җибәрә: «Аязны күрсәтмәсеннәр, карагыз аны!» Театр – ләббәйкә!.. Хәерле булсын инде...

Язучы кеше баскычның төрле араталарына утырып дөньяга күз сала. Гел-гел аста, кол булып бөкшәеп утырасы килми, гаеплемен, тәмлене тәпсерләгән чаклар да була, өскәрәк менеп карыйсы да килә. Чиратың җитеп, үзеңә язган баскыч нирсәсенә ябышырга гына торганда, шарт итеп күтеңә тибеп

---

[1] Туфан Миңнуллин турында сүз бара.

[2] Мөдәррис Мусин (1923–1994) – 1969–1984 елларда ТАССР өлкә комитеты мәдәният бүлеге мөдире.

төшерәләр! Аптырагач, күрше баскычка тотынып карыйсың, «мен!» диләр, дәртләндерәләр, хәтта арттан да этәләр. Һәм кеше акрын гына нур эзләп, яктылык эзләп читкәрәк тартыла башлый. Җылы сүзгә мохтаҗ кеше, җылы карашка! Атны гел-гел камчы белән генә куарга ярамый. Сирәк булса да солы салыгыз да башак болгатыгыз! Су эчерегез!

Нәтиҗәдә, бөкре Аяз барлыкка килә.

Төрки-татар дөньясына лидер эзләдем — табалмадым...

Читкә кагылып карадым, кояш дигәнем — эт күләгәсе булып чыкты...

Менә бүген, инде 23 мартта, иртән, беренче эшем итеп, язганымны укып чыктым да уйга калдым: эш арасында, өзек-өзек язылган, фикерләр берсе өстенә икенчесе сикерешкәннәр, мәтәлеп төшкәннәр. Әмма күчереп торырга вакыт юк, кирәк иде... (ХӘТЕР – ХАТИРӘ булып калсын).

*23 март, 1986 ел. АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ*

## Көндәлекләр

*(Өзек, 1992)*

*1992, 4 май*

### Айлы көннәрдә[1]

Моннан утыз еллар элек бер әсәремдә: «Кыр казлары безнең якларга апрель азакларында айлы төннәрдә киләләр. Өй түбәләренә тияр-тимәс каңгылдаша-каңгылдаша очалар алар»,– дип язган идем. Яз саен диярлек ишетә идем мин аларның тавышларын, айлы төннең сәфәрчеләре миңа ниндидер бөек сер бүләк итеп узалар кебек иде. Хәзер инде кыр казлары юк, апрель азагында күкләр буп-буш, ә кыр казларының каңгылдашканы күңел түрендә һаман саклана... Хәзер, уйлый-уйлый, мин бер нәтиҗәгә килдем. Нигә көндез очмаганнар сәяхәтче кошлар? Кайтыр юлларына тулган айлы кичне сайлаганнар? Моның бер хикмәте бардыр лабаса!

---

[1] Гыйләҗев А. Айлы көннәрдә (Илһам Шакировка – 60 яшь) // Сөембикә.– 1995.– № 2.– 6–7 б.

Әлбәттә, бар! Киек казларның китәр һәм кайтыр юллары һаман бер, йөз ел элек тә, өч йөз ел элек тә көзләрен алар бер юлны сайлап очканнар, юл аларның канына сеңгән, гасырлар дәвамында геннарына күчкән. Ялгышмаганнар да алар, адашмаганнар да, җир өстендәге йөзләрчә билгеләрдән чыгып, туры вә бәрәкәтле юлны сайлый алганнар... Менә монда аулак күлле урман авызы... Кунарга була. Ә бу елга тугаена төшеп, алар тамак ялгаганнар, каңгылдашып, бер-берсенә көч биргәннәр. Юлның башын да, азагын да яхшы белгәннәр, җир-сулар, урман-күлләр аларның үзгәрмәс ышанычлы маягы булган.

Берзаман адәм уллары туган-үскән бишекләре Җирне шулай бозарга тотынганнар, тиз арада аның йөзен танымаслык итеп ермачлаганнар. Кичә күл булган тын иңкүләрне киптереп, завод-фабрикалар салганнар, болын өсләрендә төтенле-сөремле шәһәрләр калкынган, елгаларны борып, кире якка кертеп җибәргәннәр, кайчандыр диңгез чайпалган бәхетле тарафларны чүл комнары ялмап йоткан. Кыр казлары үзләренә маяк иткән билгеләр беткән, алар миңгерәүләнеп, аңгыраеп калганнар, су, тереклек эзләп, анда-монда каерылганнар. Әмма Җир шарының танырлыгы калмаган инде. Елдан-ел үзгәрә барган җиргә күктән карап очкан киек казлар, ниһаять, сәфәр өчен айлы төннәрне сайлаганнар. Тулган ай аларга ялгышусыз туры юлны сайларга булышкан. Казлар, хак юлны яктыртып торган айга ышанып, ерак-ерак сәфәргә чыкканнар, һәм ай аларны берчакта да алдамаган, үзгәрмәгән, сагышлы-көмеш нуры белән күкне дә, җирне дә бердәй яктырткан.

Хәзер, апрель азакларында, айлы төннәрдә күңелем сагышланып күккә карыйм да, уем дәвам итә. Җир тормышы шулай үзгәргәндә, җир өсте шулай гарипләнгәндә, ничек яшәде татар халкы? Аның алга барыр юлын кемнәр яктыртты? Бер мәлгә Җир шарының әйләнешен туктатып уйга калсаң, исең китәрлек! Шушы канлы егерменче гасыр дәвамында гына да ниләр күрмәде татар башы! Бигрәк тә соңгы чоры дип аталган елларда! Тарих юк, аны шовинистик кара буразналар каплаган. Иман юк, аны имгәтеп, изеп бетергәннәр. «Татар, син надан, килмешәк. Октябрь революциясенә хәтле

татарларда уку-язу булмаган, китаплар басылмаган. Сезне якты киләчәккә кемнәр җитәкләп алып барганлыгын беләсезме?!» Татарлар үзләре дә яр бакалары булып бакылдашалар: «Партиягә рәхмәт! Ленинга рәхмәт!» Кыска гына арада тел югала, тарих онытыла, иман алмашына, моң саега. Һәлакәт, инкыйраз сәгатьләп түгел, минутлап якыная... Ни аяныч, әле моннан ун ел элек кенә Татарстанда чыга торган рус газеталары: «Унҗиденче елга кадәр татарларда укый-яза белгән кешеләр булмаган»,– дип яздылар, һәм без, миллионлаган татарлар, аңгыра кәҗә кебек, шуны тыңлап, сакал селкетеп разый булып тордык.

Табигатьнең шундый бөек кодрәте барлыгын мин шул елларда таныдым. Юк, учакта ут тәмам сүнеп бетми икән, нинди каты давылларда да кайдадыр утлы күмер кала, аны большевистик гарасат сүндереп, мәкерле ленинчы тәгълимат күмеп бетерә алмый икән. Юк! Учак уты бирешми. Ул саклана белә, көчен җуймый һәм нәкъ кирәкле мизгелдә генә дөрләп ала...

Күз алдына китерегез. Моннан утыз еллар элек. Нефтьчеләр мәркәзе булырга әзерләнгән Әлмәт шәһәре. Апрель азаклары. Күктә тулган ай. Өй түбәләренә тияр-тимәс кенә, җир өстенә сагышлы көмеш авазлар түгеп, киек казлар оча!.. Ул чактагы Әлмәт язы урамнарын белсәгез сез!.. Кая борылма, тездән лай, урамнарда, машиналар артыннан сызылып, сыек пычрак кала. Лайның кермәгән тишеге юк, ишегалларында да ул, тыкрыкларга да бәреп кергән, лапаслар тирәсендә ерып йөрерлек түгел. Дәүләт оешмалары алдында һәр җирдә тимер кыргычлар, су тутырылган тимер ялгашлар тора. Тездән лайны ерып-ерып киләсең дә, озаклап-интегеп, резин итекләреңне юасың... Мәктәп болдырларында йөзәрләгән аяк киемнәрен күреп имәнеп китәсең...

Мәдәният сараенда Илһам Шакировның концерты. Җырчының даны шулай бөек, ерак-еракларга таралган, шушы сазлы урамнарны үтеп, кесә фонарьлары белән юл яктыртып, бер-берсенә дәрт-көч биреп, концертка йөзәрләгән әлмәтлеләр җыелган. Тормыш берчакта да җиңел түгел, нефтьче хезмәте дә авыр, мәшәкатьле... Көннәр буе авыр торбаларны кулдан-кулга күчереп йөрткән, бетон блоклар, баганалар кү-

чергән, канау казыган әлмәтлеләр Илһам Шакировның моң диңгезенә кереп чумганнар. Сәхнәдән «Кара урман»[1] агыла... «Әниемә хат»[2] яңгырый... «Көзге ачы җилләрдә»[3] уйнап ала... «Уел»[4] башлануга, күпләрнең күзләренә кайнар яшьләр килеп бөялә. Һәрбер җыр йөрәкләрне милләт белән, учакта җемелдәп яткан күмер чаткылары белән таныштыра. Залда басып торучылар да күп, ишек-тәрәзәләргә адәмнәр килеп бөялгән, җырчыны сәхнәгә кат-кат чакыралар. Берәүнең дә бу кичтән аерыласы, бәхет диңгезеннән чыгасы килми, зал берләшә, әлмәтлеләр бер сулыш белән сулыйлар – аларның шушы кадәр бердәм, тату, бөек булганнары юк иде...

Менә концерт тәмам... Халык, ишелеп, бәхет диңгезеннән караңгы, дымлы, суык һәм пычрак урамнарга тарала. Ләкин алар хәзер бөтенләй үзгә халык, лайның-ботканың күзенә чәчрәтеп басалар, күңелләр яп-якты, сүзләр түгәрәк, алар үзгәргәннәр. Көннәр буе ят телдә сөйләгән радио-телевизорларга күнеккән, эштә, әдәп саклап, сыңар рус хакына вата-җимерә русча сөйләшеп йөрергә мәҗбүр ителгән кешеләр хәзер үзгә – алар Татарлар. Ах, татар булуларын нигә алар шулай сирәк тоялар? Әйе, алар – бу кичтә бөтенләй бүтән кешеләр, алар баеп кайтып баралар, көчәеп. Әле өйләргә таралышкач та, алар дөнья мәшәкатьләрен онытып торалар, өйләрне, түрләрне яктыртып, өстәл тирәли утырышалар да рәхәтләнеп чәй эчәләр. Бер-берсенә ягымлы, кадерле сүзләр әйтәләр. Нигә алай? Ни булды? Бәлки, бик күпләр ни булганын сөйләп тә бирә алмаслар, әмма алар үзгәрешне сизәләр, аларның шушы бәхетле мизгелне озаккарак сузасы килә. Иртә таңнан нинди авыр эшләр көткәнен белгән хәлдә, алар йокларга ятарга ашыкмыйлар.

Кем уятты аларның җаннарын? Кем баетты бөек татарны? Кем ул бөек тылсымчы? Ул – Илһам Шакиров. Табигатьнең серле баласы, тиңдәшсез олуг тылсымчысы. Илһам хакында соңгы елларда күп язылды, аның хакында китаплар басылды. Әмма бөек җырчыбызның кылган гамәлләренең

[1] Татар халык җыры.

[2] Ә. Даутов сүзләре һәм көе.

[3] Татар халык җыры.

[4] Башкорт халык җыры.

олылыгын без бүген, телебез татарча ачылырга торганда, караңгы офыклар артында якты офыгыбыз да җемелдәгәндә, аермачык әйтергә тиешбез. Әгәр без бүген, егерменче гасыр ишеген ябарга җыенганда, татар җаны әзме-күпме исән калган, дип расларга телибез икән, без гасыр дәвамында татарны милләт итеп саклап калырга омтылган бөекләр турында тел яшермичә сөйлик инде. Булган алар, тарихта милләт эзен сакларга тырышучы олуг затлар булган. Минемчә, аларның иң олысы һәм иң бөеге – Илһам Шакиров. Әйе, иманны какшатканнар, үткән юлларыбызны бозып күрсәткәннәр, татар намусына пычрак ыргытканнар, ил талап түгел, җир тарап ашарына тапкан бөек милләтне, явыз итеп күрсәтеп, китапларда мәсхәрәләгәннәр. Киноларда аның барлыгын, күңелен каралтып күрсәткәннәр. Ләкин бер илбасарның да кулы җитмәслек бөек бер хәзинәсе калган татарның: ул – моң. Ил башына нинди тираннар менеп утырса да, хакимият сатлык чиновниклар, партиянең сатлык ялчылары кулына күчә торса да, тарихыбызда бер нәрсә үзгәрмәс калган: ул – татарның милли моңы. «Карурман» шул ук, шаулаган да, моңланган да. «Зиләйлүк»не[1] 1937 елларда да төрмәләргә тыга алмаганнар. «Гөлҗамал[2]»лар, «Сәгать чылбыры»[3], «Чатырлар»[4] һәм тагын бик күп көй-җырлар, татарның сихри күңел түрләрендә туган изге догалар, ленинчы караңгы елларда кимсетелеп, түбәнсетелеп киленсәләр дә сакланганнар. Табигать бушлыкны сөйми, нигә әле татар гына бу кагыйдәдән мәхрүм калырга тиеш?! Үлеп барган татар дөньясы милли кодрәт белән дөньяга моңлы улларын да чакырган. Һәм татар иле үзенең милли пәйгамбәре итеп Илһамны тудырган. Безнең моң ул – безнең милли хәзинәбез, байлыгыбыз. Дөрес, алтын кисәкләре кебек, ул банкларның җиргә сеңгән яшерен базларында сакланмый, әмма ул бар, һәм аның бәясе елдан-ел арта тора. Әнә шул моң байлыгын кайтарып биреп, халкыбызны бәхетле, бай, горур, мәгъруур һәм көчле иткән асыл зат ул Илһам Шакиров. Әнә шуңа да авыр эштән талган әлмәтлеләр йокы-

[1] Татар халык җыры.

[2] Татар халык җыры.

[3] Татар халык җыры.

[4] Зөлфәт сүзләренә язылган татар халык көе.

га китә алмыйлар, алар ирексездән үзләренә-үзләре бүтәнчә күз белән, татар булып, горур, бай татар булып карыйлар. Халкыбыз күңелендәге якты шәмне ничә еллар сүндерми саклады Җырчыбыз! Ерак чүл шәһәрләренә барып җитте, караңгы тайгаларны яктыртты, илне ташларга мәҗбүр ителгән илгәзәкләрне дә эзләп таба алды. Ни өчен сөймәделәр аны партократлар, милләтсатарлар? Чөнки Илһам аларның йоткылыгына ярамаган Милли моңыбыз сагында торды.

Әгәр кайчан исә бер, татар җөмһүрияте ныгып, илебез башына батырлар килә калса, алар, тәвәккәлләп, татарның үз бүләкләрен – орденнарын булдырсалар, ул хөрмәткә беренче нәүбәттә озак еллар татар язмышы сагында торган бөекләребез – Илһам Шакиров, Әбрар Кәримуллин, Миркасыйм Госмановлар лаек. Орден дигәч, нигәдер мыек тырпая, совет орденнарын мулрак сөт биргән кәҗәгә дә тактылар. Ләкин биеклекне раслый, данлый торган бүтәнчә чаралар юк шикелле. Орденның да кадерен саклый белергә кирәк! Югыйсә орденнардагы алтын да тутыга! Менә гаҗәп!

Сүз башлар алдыннан, мин иң газиз, иң кадерле ике кешене күз алдында тоткан идем. Татар халкын татар итеп саклау җәһәтеннән искиткеч гүзәл эш башкарган икенче гали зат итеп, бүген менә драматург Шәриф Хөсәеновны мөнбәргә менгерәм[1]. Гали зат, күңеле тутыкмас зур драматург. Шәрифнең эшчәнлеген җыеп кына күз алдына китерә алмаган кайберәүләр өчен бу зур бәя көтмәгәнчәрәк тә булыр. Уйлыйк, уйлашыйк. Шушы караңгы елларда яшәп, талантларга юл чикләнгән дәвердә иҗат иткән Шәриф Хөсәеновның чишмә башына күз салыйк.

Шәриф Хөсәенов иҗатына мәгълүм бер вакытларда белгечләрнең, фән-театр әһелләренең җылы карашы төшкәләп куйса да, аның шактый еллардан дәвам итеп килгән бәрәкәтле иҗатын тулаем бербөтен итеп карап, әдипнең иҗаты аша без үткән катлаулы чорны анализлаган хезмәт әлегә юк. Кызганыч! Шәрифнең 60 еллыгына исәп тотып чыгарылган «Мәхәббәт сагышы» дип исемләнгән күләмле җыентыкта

[1] Гыйләҗев А. Онытылмаслык эшләр калдырып китте (Шәриф Хөсәеновның 70 еллыгы уңае белән, аның турында) // Казан утлары.– 1999.– № 11.– 189–190 б.

да гадәттәге кереш сүз юк, һич булмаса, соңгы сүз дә әйтелмәгән. Мин бу хәлнең сәбәбен болайдыр дип уйлыйм: драматургия белгечләреннән берәүнең дә Шәриф Хөсәеновның үтә гыйбрәтле, үрнәк иҗатын бүгенге көннән торып бәһаләргә көче җитмәгән. Ә андый тугры хөкем, гадел анализ, хаклы бәя бүген кирәк иде. Бүген, милли яңарыш дип авыз ачканда, Шәриф Хөсәенов иҗаты аша байтак гыйбрәтләрне халыкка җиткерергә кирәк иде!

Театрларның атлар-атламас яшәгән соры еллары! Уйламаганда-көтмәгәндә, телләргә яшь драматург Шәриф Хөсәенов исеме килеп керде. Бу исемне халык арасында беркеткән тәүге әсәр, ялгышмасам, «Профессор кияве»[1] пьесасы булды. Әсәрнең язылу елына игътибар итик. 1951 елда язылган икән. Моннан кырык ел элек! Әле «халыклар юлбашчысы» Сталин исән. Әле әдәбиятта, сәнгатьтә «социалистик реализм» дигән сөремле, кара, чын талантларның юлын тимер йозаклар белән бикли торган ялган, шомлы теория өстенлек итә. Әдәбият-сәнгатьнең хак сүзгә омтылган талантларын, бигрәк тә кавырсыннары катмаган өметле яшьләрне шушы ялган теория белән изәләр. Соцреализмның бер-ике цитатасын ятлаган обком инструкторлары, әдипләр каршысына чыгып, бүксә киереп, ничек иҗат итәргә кирәклеген өйрәтәләр. Әйе, бу теория талантсызларга киң юл ачты, әрсез каләм ияләренә әсәр арты әсәр тәгәрәтергә мөмкинлек бирде. Син каләмгә тотынганчы ук, өстән сиңа юл сызып төшерелгән, барыр юлыңның як-ягына, Ленин-Сталиннан йолкыштырып, маяклар кадап куелган. Кагыйдә бер: әсәр үзәгендә, һич икеләнүсез, уңай герой булырга тиеш. Син күтәрергә теләгән мәсьәлә, олымы ул, кечеме, әнә шул уңай персонаж аша хәл ителергә тиеш. Бу – какшамас закон! Ничәмә-ничә буын язучылары, шул каһәр суккан уңай геройга яңа сыйфатлар тагып, болай да Яңа ел чыршысы сыман ялтыравыклы, шалтыравыклы бизәкләр белән сырланган чүпрәк курчакны чын кеше, заманның вәкаләтле илчесе буларак тәкъдим итеп интектеләр. Күп очракларда уңай герой партия хезмәткәре

[1] Ш. Хөсәенов пьесасы (1958).

булды, Павлик Морозов[1], Павел Власов[2] һәм Пашка Корчагиннарның[3] дәвамчысы уңган комсомолец иде, ул, ахыр чиктә, совет хакимиятенең тугры ялчысы прокурор, һич югында, карт большевик образлары, битлекләрен дә алыштырмыйча, әсәрдән әсәргә күчеп йөрде. Мондый персонажлар әсәр вакыйгаларына, пьесалар тукымасына катнашып китә алмасалар да, соңгы сүзне алар әйтте, хөкем хокукы аларның бәлтерәгән канлы кулларында булды. Мондый хәл совет әдәбиятының бөтен тармакларында яшәп килде. Театрларда төче ялганга корылган, бары тик деректив органнарның кәефенә ярарга тырышып кына язылган корама әсәрләр бербер артлы, бер-берсенә өзелмәс ялганып, иҗат әһелләренең талантларын да бер калыпка сугып таптаган пьесалар яшәгән авыр дәвер – илленче еллар! Егерменче яшен тутырып үткән Шәриф Хөсәенов әнә шундый шартларда шытып, үсеп чыга. «Профессор кияве» татар тамашачысы зарыккан күңелгә хак сүз әйтергә талпынучы комедия була. Шушы форсаттан файдаланып, «кияү» ролен башкарган яшьтәшем, арабыздан иртә киткән талантлы артист Вәкил Закировны бүген зур хөрмәт белән яд итәсем килә! Дөрес, әле бу комедиядә чынбарлыкны, совет системасын аркылыга-буйга телә, турый алучы әче телле, туры сүзле Шәриф Хөсәенов юк, мәгәр бер хакыйкатьне чатнатып әйтергә кирәк: шушы беренче пьесада ук аның сюжетында, фикер сөрешендә Шәриф Хөсәенов дигән талантлы әдипнең иҗат нигезен, үсешен тәэмин итәчәк тирән, дөньяви һәм аңлы гуманизм бар. Ул кимсетелгәннәр ягында. Ул дөнья, совет системасы бозган профессор белән бәхәскә керә ала. Һәм бу хаклы, дәлилле бәхәсен адашкан, саташкан, мәрткә киткән ваемсыз-гамьсез совет татарлары белән уртаклаша да. Бу спектакльгә тамашачы, бигрәк тә студент яшьләр кырылып йөрде. Алар сәхнәгә чыгып баскан «кияү» белән күзгә-күз очрашырга ашыктылар һәм алданма-

[1] Павел Трофимович Морозов (1918–1932) – герой-пионер, әтисен яклап кулакларга каршы чыга, ләкин бу адымы аның үлем белән тәгәлләнә.

[2] М. Горькийның «Мать» романындагы герой-революционер.

[3] А. Островскийның «Как закалялась сталь» (1932) романындагы герой.

дылар. Бу комедиядә үк сизелерлек чагылыш тапкан социаль мотивлар Шәриф Хөсәеновның чираттагы әсәрләрендә тирәнәяләр, тормышчан яңгыраш табалар, ныгыйлар. Алдагы әсәрләрендә Шәриф Хөсәенов – тирән психолог, философ һәм гаделлек җырчысы. Без бер-бер артлы татар драматургиясенең классик әсәрләре «Әни килде» (соңгы исеме «Әниемнең ак күлмәге»)[1] һәм «Зөбәйдә – адәм баласы»[2] трагикомедияләрен кабул итеп алдык. Кабул иттек тә аерылышмадык. Бу әсәрләр татар драматургиясенең казанышларына, классикага әйләнделәр. Классик дип алар шуңа саналалар, ил башында кемнәр утыруына, илдә нинди хакимият булуга карамастан, власть башында утыручылар (ә алар бик сирәк гадел булалар! Адәм балалары – властьны, ә власть адәм балаларын тиз-тиз боза!) нинди уй-фикерне түбәндәге халыкка сеңдерергә тырышмасыннар, классик әсәрләр берчакта да үзгәрмиләр, алар һәр чор өчен зарур, кыйммәтле фикергә ия булалар, һәр чорны гадел аңлатырлык, һәр дәвер кешеләренә тәэсир ясарлык көчкә ияләр.

«Зөбәйдә – адәм баласы» – 1961, «Әни килде» 1968 елларда язылганнар. Сәнгать-әдәбият өчен җиңел еллар димәс идем мин! Әйе, бу елларда татар драматургиясенә яңа көчләр килә башлады. Хәй Вахит[3], Юныс Әминов[4]лар татар сәхнәсенә яңачарак сулыш өрделәр, ләкин без барыбыз да диярлек совет власте тирбәткән татлы йокыда идек әле. Үзебезнең нинди олы ахмаклыклар эшләвебезгә хисап бирмичә, Татарстан нефтьчеләренә багышлап пьеса арты пьесалар яздык. Мактандык, макталдык, Әлмәт якларына барып, күкрәк кагып йөрдек. Ни аяныч! Бәгыребездән өзеп озаткан ике миллиард тонна нефтьнең кая китүе белән кызыксынмыйча, ни әйтсәләр, шуңа ышанып, үзебезне күрәләтә талауларына

---

[1] Ш. Хөсәеновның 1968 елда язылган драмасы (беренче исеме – «Әни килде»).

[2] Ш. Хөсәенов пьесасы (1961).

[3] Габделхәй Каюм улы Вахитов (1918–1978) – драматург. ТАССРның (1968) һәм РСФСРның (1983) атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык шагыйре (1993).

[4] Юныс Шәрип улы Әминов (1921–1982) – татар драматургы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

куанып, кул чабып утырдык! Дөньядагы бөтен канлы эшләргә ярдәм итте татар нефте, кыйтгаларны корал белән күмде, партия җитәкчеләре нефть сатудан килгән алтыннарны чит ил банкларына күчереп өлгерделәр, дөньяның бөтен канлы, дәһшәтле диктаторларын тәхеттә тотты татар нефте, переворотлар ясалды, Ленинның империалистик тәгълиматын илләргә таратты, сугыштырды, кырды, үтерде. Без халкыбызны алдап, аның күзенә төтен җибәреп, колагын балавызлап яшәдек. Оят, хурлык!

Ләкин татарда асыл затлар да булды. Драматургиядә ул бер Шәриф Хөсәенов иде. Безгә орденнар тактылар, депутат иттеләр, лауреат ясадылар. Ул бөтенләй башка юлны – хак юлны сайлады. Ул халыкның аңын үстерде, хис тәрбияләде, милли хәтерне нгытырга ярдәм итте. Бу кадәрле ныклык, кыюлык аңа каян килгәндер, ничек итеп яшьтән ныгыган иманын саклап кала алгандыр, анысын тикшерү – алдагы көннәр эше, мәгәр без кызыл авызланып йөргән елларда, Шәриф Хөсәенов Ленин–Маркларның адәм җаннарына астыртын гына җимерү инстинкты сеңдерүче тәгълиматының хикмәтен аңлап кына калмады, йодрыгын җиң эченә яшерергә гадәтләнгән халыкка совет системасының канлы чынбарлыгын ачу юнәлешендә иҗат итте.

«Әни килде» әсәрен күз алдына китерик. Изге ананың үз балалары, газизләре. Нигә шулкадәр мәрхәмәтсез, шәфкатьсез алар? Нигә чәчрәп торган рухи гарипләр?! Әдип тормышыбызны оста хирург кебек ярып җибәрә дә яшәешебезнең бөтен катламнарын җете күзе белән капшап чыга. Бу әсәрдә тормышыбызның бөтен катлам вәкилләре бар диярлек. Ленинизмның тоткасы дип игълан ителгән «пырлитар»га кадәр бар. Яше-карты, олысы-кечесе бер мәйданда укмаша. Ни хәл итәсең, коммунистик әхлак нормалары: шәфкатьсезлек, саранлык, комсызлык, күремсезлек, наркомания, аракы эчү, ялган сүз, ясалмалык изге татар Анасының газиз балаларын чеп-чи большевик ясаган. Партиядә булмаганнар да инде кешелектән чыккан. Үз аналарына шундый мөнәсәбәттә булган бу адәм тәганәләре бүтәннәргә карата нинди була алалар соң?! Моны күз алдына китерү кыен түгел. Әсәрдәге иң җитди, иң олы кисәтү әнә шул.

Бүгенге буталыш чорында безнең кайбер өлгер яшьләр дә, өлкәннәр дә, мемуарлар язып, үзләренең үткәннәрен балга манчып тасвир итәргә яраталар. Кысыр яшәешләреннән, ике-өч битлек иҗатларыннан ярма бөртеге кадәр булса да гаделлек эзләп табарга омтылалар. Булгандыр, чорны аңлаган, чорга ачыргаланган затлар да очраштыргандыр. Әмма ул затларның аңнары һәм кылган гамәлләре берчакта да халыкка акыл булып ирешә алмады, йөрәкләренең зәгыйфь тибешләре милләтебез яшәешендә юлдаш, үткәннәргә – ачкыч, киләчәккә ярдәмче ролен үтәмәде. Шәриф Хөсәенов татар әдәбиятында үзенең гүзәл пьесалары аша чорыбызның һәлакәт мотивларын кыю рәвештә, түкми-чәчми, җанлы образлар, истә кала торган фикерләре аша сәхнәдән торып халыкка ачып бирде.

Япь-яшь Зөбәйдәнең җаны талпынуларына игътибар итик. Мәшһүр артисткабыз Наилә ханым Гәрәеваның уены ул чакта беркемне дә битараф калдырмагандыр! Бу әсәрдә «Әни килде»дән үзгә персонажлар. Яшәү шартлары да, яшәү максатлары да бүтәнчәрәк. Зөбәйдә кеше булырга тели, чын кешеләрчә яшәргә омтыла. Аның гадел, хак буласы килә. Ләкин теләк – бер нәрсә, ә үзең яшәгән мохит, аның туктаусыз аяусызлыгы, хаксызлыгы синең аягыңа богау булып урала, таш булып иярә. Зөбәйдәгә яшәү җиңел түгел, алда да җиңел булырга охшамаган.

Бер бик мөһим фактны искәртеп китик: татар драматургиясендә «Әни килде» пьесасы кебек күп уйналган әсәр юк. Аны Мирхәйдәр Фәйзинең[1] мәңге сүнмәс «Галиябану»[2] пьесасы белән генә рәттән куеп була. Шәриф Хөсәенов тәкъдим иткән Ана фаҗигасен илебезнең күп халыклары, бик күп театрлар кабул итеп алды. Һәм ышанып әйтергә була: әгәр без «кузгатырга теләсәк халык күңелен», яхшылыкка, гаделлеккә омтылыш тәрбияләргә теләсәк, алдагы катлаулы көннәребездә дә бу әсәргә әйләнеп кайтачакбыз әле. Шәриф

---

[1] Мирхәйдәр Мостафа улы Фәйзуллин (1891–1928) – татар совет драматургиясенең классигы.

[2] М. Фәйзинең 4 пәрдәле музыкаль драмасы. 1916 елда иҗат ителә. «Ширкәт» труппасы тарафыннан 1917 елның 19 мартында Оренбург шәһәрендә куела.

Хөсәенов әсәрләрендәге аяусыз хакыйкать, драматургиянең иң гүзәл алымнары белән язылып, һәрберсе аерым мәкаль, әйтем булып китәрлек үткен репликалар, җанлы өзлексез хәрәкәт, тиңсез тәэсир көче – безнең милли иманны раслау юлындагы ышанычлы тутыкмас коралларыбыз ул.

Шәриф Хөсәенов әз яза, дип чеметкәләүчеләр очраштырды. «Әз булсын, тәмле булсын!» – ди татар. Шәриф каләменнән тамган һәр ым, һәр сүз, һәр фикер халкыбыз зарыгып көтеп алган Сүз булды. «Мәхәббәт сагышы» повесте «Совет әдәбияты» журналында басылганда, мин анда эшли идем. Ышанып әйтә алам, әсәр басылгач, милләтебездә яңа, моңарчы күрелмәгән бер катлам укучылар пәйда булды. Әсәр герое Хәбир Сыртланов яшьләр арасында иң популяр кешегә әйләнде. Повесть байтак еллар китап булып чыга алмады, тыеп тордылар, укучылар журналны хатлар белән күмделәр. Кайчан чыга? Кайчан русчага тәрҗемә ителә? Телен оныткан иркә туташлар да бу әсәргә ябырылды, «аңлар өчен, татарча өйрәнәбез» дип яздылар. Менә эш кая барып җитте! Бер караганда, гади сюжетка корылган, ә, нигездә, кешелекнең мәңгелек каршылыкларына багышланган бу гүзәл әсәр әлегәчә күләгәдә калып килә.

«Егерме ел үткәч» – бер пәрдәлек кенә пьеса[1]. Шәриф Хөсәеновның бу әсәре дә ил киңлекләрендә эзсез үтмәде. Абруйлы «Театр» журналы аны русчага тәрҗемә итеп таратты. Төрле төбәкләрдә йөзләрчә театрлар бу яңа сүзле пьесага ябырылдылар. Дүрт-биш кешенең фаҗигале язмышын эченә сыйдырган бу әсәр Шәрифнең сугышка, ул китергән фаҗигаләргә мөнәсәбәттә сүзе, кабатланмас хөкеме иде.

Хак сүз, Илһам Шакиров кебек үк, Шәриф Хөсәенов та татар өчен караңгы елларда халыкның күңел күгендә янган якты ай булды.

Быел, ел башында, әдәби казанышларыбызны тикшереп, Тукай бүләгенә кандидатлар сайлаганда, мин Шәриф Хөсәеновның да исемен атаган идем. Күпчелек аның бик күптәннән бүләккә лаек булып та, һич сәбәпсез күңелебездән китеп торуын искә төшерде, арадан бер иптәш, Шәриф кандидатурасы телгә кергәндә чыгып йөргән, үзе дә абруйлы, та-

[1] Ш. Хөсәеновның повесте (1965).

лантлы шагыйрь, һич көтмәгәндә: «Кем казып чыгарды бу исемне?!» – дип сүз кыстырды. Шул минутта йөрәгем өзелеп төшкәндәй булды...

Ни аяныч: без – кадерсез һәм хәтерсез милләт шул! Үз кадеребезне дә, аерым шәхесләр кадерен дә саклый белмибез. Ә милли каһарманнардан тыш халык бербөтен булып яши алмый. Башкортлар Салаватларын[1] берчакта да онытмаганнар. Һәм башкортның батыр улы Салават аларга бербөтен булып оешып яшәргә бүген дә ярдәм итә. Галәмгә очкан Андриян Николаев[2], чуваш халкына җылы яшәү биреп, йөз елларгача көч өстәп торачак. Үткән гасыр батырларын без буыннан-буынга күчерә алмаганбыз. Татар җирендә исемсез батырлар гына чәчелеп калган. Нишлисең, терсәкне тешләр идең дә... булмый, барып чыкмый!

Гасыр азагына таба мескен татарның да хәле яхшырыр сыман. Шушы караңгы дәвердә милләтнең күзен ачарга тырышкан, аңа терек суы өреп торган милли каһарманнарыбызга телдән генә булса да һәйкәл кою – хәзер җирдә яшәгән буыннарның да изге бурычы. Күгебезгә алтын аебыз менде. Без хәзер айлы төннәрдә генә түгел, айлы көннәрдә дә яшибез. Ләкин безнең барыр юлыбызга киртәләр коручылар, адаштыручылар әле әз булмас! Ходай сакласын!

Илһам Шакиров, Гамил Афзал, Шәриф Хөсәенов, Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев кебек милли каһарманнарыбыз безгә – замандашларыбызга – туры юлны балкытып торсыннар! Амин!

*1992, 22 июнь*

*Займище*

Сугыш башланган иң озын һәм тарихта аерым урын алган дәһшәтле көн. Дачада бер башым. Кайнарланып эшкә ябышасы килә... җитез ялкаулык баса. Кан ләпшердек тамыр-

---

[1] Салават Юлаев (1752–1800) – башкорт халкының милли батыры, шагыйрь, Емельян Пугачёвның көрәштәше, 1773–1775 елларда крестьян сугышы җитәкчеләренең берсе.

[2] Андриян Григорьевич Николаев (1929–2004) – СССР космонавты, авиация генерал-майоры. Ике тапкыр Советлар Союзы герое.

ларым аша кирегә ага сыман. Нык кителгән карт күңелнең үткер очлы ярчыклары һаман, һаман читкә, еракка чәчелә. Күңел – чәлпәрәмә килгән юка көзге ул! Кем җыяр аның ярчыкларын? Җыеп, аңа карап, ни дә булса танылырмы? Аларны җыеп алмак юктыр инде, бусына иманым камил.

Яңа әсәргә[1] «Карцер» дип аталган бер бүлемтек:

«Дүрт йөз кешелек булып, биш йөзне сыйдырган тәбәнәк барак, төн урталары авышкач, беразга тына. Тынлык чамалы, ул сүзне авыз тутырып әйтергә дә ярамый, секциядән секциягә йөрүләр туктала тукталуын... Дөп-дөп басып, чүмәлә хәтле гәүдәсен туры тотып, иң актыккы кеше булып бригадир кайта. Алар барак старостасы янында гәп сугып утырганнар. Ул кайтып керүгә, йокламаганнар да салам матрасларга сеңә. Аның нинди кәеф белән кайтуын кем белә?! Николай Хохун, җирән чәчле бандеровчы, үз якыннары белән дә аз сөйләшә. Западникларның телен әлегә мин бөтенләй аңламыйм, ә Хохунның – безгә боерык кына бирә торган каты телле хохолның – ярты сүзен дә аңламыйм. Тел аңламаганда, кешенең күзенә, йөзенә карыйсың. Мин Хохунга күтәрелеп карарга да, йөзен җентекләп өйрәнергә дә куркам. Килгән шәптә үк мин аның сибиряк Миша Пермяковны кыйнаганын күрдем. Йа Ходa! Үлмәсә дә үлми икән кеше...»

*1992, 23 июнь*
*Займище*

Кичә, тулгак тоткан мачы сыман, көне буе диярлек өстәл тирәли әйләнгәләдем. «Башлыйм!» дип утырып карыйм. Юк кына бит, уйларым иртәнге сыек томан кебек тыела алмыйча таралалар. Ятам, фикерем, күз нурларым аша түгелмәсен дип, күзләремне чытырдатып йомам – сикереп торып эшкә ябышырлык уйлар килми. Бүген бик начар йокладым. Урыным кыршылган иске ияр сыман җайсыз: әле бер якка, әле икенчесенә янтая. Мендәр искәрмәс күтәрелгән судагы үрдәк оясы шикелле күчеп йөри. Һава тыгыз, күкрәк читлеген баса, йөрәкне кыса. Гүя үземә таман коелмаган калкан кигәнмен. Иртән баш чатнап уяндым. Махмырмыни! Ятам

[1] А. Гыйләҗевнең 1991–1993 елларда язылган «Йәгез, бер дога!» романы турында сүз бара.

шулай, кара түшәмнән аклык эзләп. Ятак белән түшәм сүз берләшкәннәрмени, бер-берсенә һаман тартылалар. Мин ятам сандал белән авыр чүкеч арасында уфырдап. Ми ярымшарлары аша туктаусыз үтеп торган тонна-тонна уйлардан ничек йөрәк ярылмый? Уйларның – максаты, максатның юнәлеше булса икән! Ходаем, минем баш аша үткән уйлардан ни мәгънә? Алар берәүгә дә, хәтта үземә дә кирәкмиләр ич! Яңа әсәремнең «Карцер» дигән бүлеген тырмаштырып куярмын дигән идем. Ничәмә-ничә кат күңел җилгәргече аша үткәрдем мин Карабас карцерын? Утырсаң язылмый. Язарга, ул тәмуг минутларыннан котылырга, җанны хатирәләр төрмәсеннән ычкындырырга бик вакыт лабаса! Нигә адәм күңеленә хатирәләрнең иң татлылары әйләнеп кайтмый икән? Әллә якты хатирәләр дә, күңел авырлыгыннан котылырга маташканда истәлекләрнең караларына манчылып, дегеттәй каралалармы? Һәркемнең үз хәтере, явыз хәтерләр дә була, алар даим-даим үчегәләр, пыскып төтиләр, хәзергене сөремгә урыйлар.

Эш тукталган картаю мизгелләрендә һаман иске «Совет әдәбияты», «Казан утлары» журналларын актарам. Өр-яңадан Ә. Еники, Ш. Хөсәенов, Г. Афзал әсәрләрен укыштырам, Г. Әпсәләмов, Хәсән Хәйри язмаларын, борынымны тотыптотып, күздән кичерәм. Большевизм исенә һич чыдап булмый. Сирәк-сирәк очрашып сөйләшкәндә, мәрхүм Шәрәф Мөдәррис[1] акыллы гына кеше булып күзгә күренә иде. Бүгеннән торып язганнарын укып карасаң... егылып китәрлек! Коммунистларның ялчысы, большевизм каланчасының иң очында торып агу-ялган таратучы булган икән. Икейөзле дисәң, моны ничек аңлатырга? Әйе, әтисе хак коммунист булган. Яшьтән үк авыл ярлылары, агач большевикларга катышып, Ленин идеяләрен үткәргән. Мөдәррис малай чакта ук, әтисе итәгенә тагылып, авыл активы арасында «өметле большевик» булып саналган.

Мин дә яшь чактан ук шактый тере, җитез һәм зиһенле малай идем. Егет булдым, ир дәрәҗәсе алдым. Бик күпләр белән аралаштым, уй-фикер бүлештем, берчакта да больше-

[1] Шәрәф Хасиятулла улы Мөдәррисов (1919–1963) – шагыйрь, публицист, тәрҗемәче

визмны тулаем яклаган кешене очратмадым. Бәлки, коммунизм ялчылары минем алда ачылып бетмәгәннәрдер? Ә Шәрәф кебек үзләренә тартылган кызыл авызларны тумыштан ук аерып алганнардыр? Укыйм, шаккатам: Шәрәфнең мул публицистикасында ник бер хак сүз булсын! Эчеп үлде бичара, салмыш иде, аның шешә белән никахлашкан соңгы еллары хакында ничаклы анекдотлар йөри! Нигә мавыкты ул аракы белән, нигә акыллы башын шешәгә бирде? Хәзер уйлап ятам, җүләр түгел иде лә егет, телдән усал, әмма хак фикерләр ычкындыргалый иде. Талантлы адәм эчкегә сабыша икән, моның бер-бер сәбәбе булмый калмый. Бәлки, мәрхүм үзенең берне уйлап, икенчене – капма-каршыны сөйләп яшәвен сизеп, кая куярга белмичә, җанын шешә дигән явызга тапшыргандыр. Гаиләсен, язучы хатыны Ләбибәне[1], балачагасын уйлап, чынлыгын тырышып-тырышып яшергәндер. Якыннары, туганнары арасыннан берәвесен Черек күл баткагы йотмадымы икән? Андый хәл дә бик күпләрне өркетеп яшәтте. Ялганчы, канечкеч Ленинның шулкадәр [...] бул инде! Талант ияләренең юлына таяк тыгыла башлагач, алар, безнең илдәге гадәт буенча, аракыга табындылар. «Юность»[2] журналының 1989 елгы 7 нче санында мәшһүр җырчы Галина Вишневскаяның[3] «Солженицын и Ростропович[4]» исемле фактларга бик бай мәкаләсе бар. Ростроповичка да ямьсез еллар килеп җитә. «Значит, каждый раз нужно было идти на творческий компромисс, постепенно снижать свой исполнительский уровень, приспосабливаться к посредственнос-

---

[1] Ләбибә Фәез кызы Ихсанова (1923–2010) – язучы. ТАССРның (1972) һәм РСФСРның (1983) атказанган мәдәният хезмәткәре.

[2] Мәскәүдә 1955 елдан нәшер ителүче әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси айлык журнал.

[3] Галина Павловна Вишневская (Иванова, 1926–2012) – совет опера җырчысы, актриса, театр режиссёры, педагог. СССРның халык артисты (1966).

[4] Мстислав Леопольдович Ростропович (1927–2007) – рус совет виолончелисты, пианист, дирижёр, педагог. СССРның халык артисты (1966), Ленин (1964), Сталин (1951) һәм Россия (1991, 1995) Дәүләт премияләре лауреаты, биш тапкыр Грэмми премиясе лауреаты.

ти. В этих случаях на помощь по старой русской традиции приходит водка, а Ростропович не оказался исключением». Рәсәй татары русның үзеннән мең кәррә арттырып җибәрә ләбаса! Күпме кешеләребезне, «аракы» дип аталган көймәгә утыртып, без икенче дөньяга озаттык. Бик күп! Тик без милләт вәкилләренең шәхси фаҗигаләреннән аракы ярдәмендә котылырга теләгәнен берчакта да авыз тутырып әйтмәдек! Татар – битлек кияргә остарган, йөзен яшерергә күнеккән, чынлыкны танырга дигәндә көчсез милләт.

Сорау алганда, төрмәдә чакта, дим, никадәр Шәрәф Мөдәррис хакында кат-кат, явызланып сорадылар. Минем җавапларым «дело»да сакланадыр да әле. Горшенин[1] аңа яла ягтырырга теләп, ничә көннәр тырышты. Нишлисең, ул чакта түгел, бүген, үземә алтмыш биш яшь тулып килгәндә, минем яшемә дә җитми һәлак булган Шәрәф хакында колакка әләрлек бер сүз дә әйтә алмыйм. И Тәңрем, табигать тарафыннан талант иясе итеп сайланган, үз чынлыкларын халкына күрсәтеп өлгермәгән күпме бичаралар бар татар тарихында?! Фаҗигаләрен тарихи шартлардан чыгып дәлилли алмадык, талантлар үлеме аша чорыбызның явызлыгын, мәрхәмәтсезлеген дөньяга фаш итәргә көчебездән килмәде! Аңлыйм, Х. Хәйри, Г. Әпсәләмов, Ибр. Газиләр шул юлга бер баскач, большевизм бизгәгеннән арына алмадылар. Әле күптән түгел Әмирхан абый идарә утырышында әйтә торды: «Ибраһим Гази «татар теленең гомере чикле, ул үз җае белән бетәргә тиеш... Аңа бердәнбер юл – һаләкәт!» дип саный иде», – диде. Ибр. Гази, Х. Хәйриләр, үз заманнары мөмкин кылганча, бай, иркен вә мул яшәделәр. Ә Шәрәф?! Такта арасына ярым черек пычкы чүбе тутырылган дымлы почмаклы тәбәнәк өйдә яшәп интеккән язучы бит! Фронтовик!

Бар иде бездә андый мәхлуклар, аерым паёк та ашамадылар, байлар шифаханәсендә дә дәваланмадылар. Фәкыйрьфокралар иде алар. Әмирхан Еники гомер-гомергә аерым паёк ашады һәм өлкә комитеты әгъзалары гына дәвалана алган палаталарда атаклы табиблар кулыннан дәва алды. Нигә алай? Кем белсен!

[1] Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгы (МГБ) майоры.

Бәлки, телнең киләчәген күздә тотканда, Ибр. Гази хаклы да булгандыр?! Үзем дә шулай уйламыйммыни? Аерма шунда ки, Ибр. Гази бу фактны салкын акыл белән, битараф буларак беркетеп куйса, мин җан ачысы белән, тилмереп, кычкырып язып куям.

*1992, 24 июнь*
*Займище*

Таңнан тордым. Бер башым. Яшел җәтмәдәй урман-офыкны аралап, басынкы кояш чыкты. Бүлмәмнең тишек-тошыкларыннан җил бәрә. Быелгы кояш боз керфекле булыр, дип юраганнар иде, шуңа охшаган. Өченчекөн Пучы[1] егете – студент Марат Шакиров килеп киткән иде, «безнең якларда майдан бирле тамчы да яңгыр төшкәне юк» дип сөйләп торды. Кайгы сүзләрен тәкрарлап арыган телләргә тагын «корылык» дигән яман сүз керде. Җитмәгән иде инде быелгы бәла-казалар! Әгәр уңыш булмый икән – ач калачакбыз. [...]

*1992, 4 июль*
*Займище*

Киң җиһанның эсселеге йөзләрчә градуска җитүен, олы вә кече илләрнең мең елларда да көйләнмәгән язмышын, Җир һәм Күкнең шашынып бәргәләнүләрен, аерым кешеләрнең күз чокырына кереп оялаган дәһшәтле тойгыларны бер сүз белән әйтеп бетереп була икән. Ул сүз татарча – ШОМ. Күзнең кара төсләрне күрү сәләте бермә-бер артты, тонган колак зар-моңның иң нәзек авазларын да ишетә, күңел Җир шарын пәрәвездәй сарган бөтен энергияләргә сак, табигатьнең, җәмгыятьнең бар халәтен бер сүзгә шыплып сыйдырып була – ШОМ!

1 июльдә коега суга барам, якындагы сүзсез урманны уятып, күке кычкыра. Язын, үз вакытында, күкеләр, курка-курка гына аваз салып, җиһанда барлыкларын белдергәннәр иде. Иң гаҗәбе: күкеләр түбәндә, куак астында кычкыргандай булдылар. Бүген, минем хәсрәтемне арттырып, биек агач-

[1] Татарстан Республикасы Актаныш районындагы авыл. Чаллы – Уфа юлының уң ягында урнашкан.

ның нәкъ очыннан тилереп кычкыралар. Шомлы яз! Шомлы күкеләр! Быел сыерчыклар килмәде, ничәнче яз Займищеда оя ясамыйлар алар. Чәпчекләр дә ашык-пошык кына күренделәр дә югалдылар. Керәшәләр дә күз нуры ирешмәслек югарылыкка чаж-чож очалар. Тугры чыпчыклар күренми, якын дусларым – чибәр песнәкләр – мөгаен, урмандадыр. Тимер юлга юл күрсәтеп үскән рушада[1] пар сандугачлар адым саен диярлек сайрашалар, дөньяны матурлыкка өндиләр иде. Быел ник берәвесе ялгышып сайрап җибәрсен. Безгә язган югары күк астында карга белән саескан гына калды. Каргалар иблис сызган план нигезендә, бомба ташларга әзерләнгән шомлы күләгәләр булып, күкне бүлешеп алдылар. Элгәрге елларда тимер тешле саесканнар, кеше тораклары янына якынаерга шүрләп, читтән-читтән генә яныйлар иде... Быел!.. Күзеңә карап, кылыч койрыкларын селки-селки, түбәңне чукырга җыеналар. Кая ул курку! Кая ул сагаю! «Сайрар кошларыгызны ашап симердек, хәзер үзегезне чукырга тотынабыз!» диләрме? «Иң элек бала-чагаларыгызның күзләрен чукып чыгарачакбыз!» диләрме?

Июньнең соңгы көннәрендә Кызыл Байракка[2] барган идем, ике көнгә, Нәкыя белән. Сихри урыннар! Иделнең аулак диярлек ягасы. Нарат урманнары. Текә ярлы тирән чокырлар. Мең төрле чәчкә-гөлләр көнгә карап тирбәләләр. Болын җилләренә сөенешеп, кылганнар йөгерешә. Безнең якларда әз-мәз качып калган дала кылганнары. Учак урыннары. Төтен исләре. Каяндыр, үр өстеннән тимер очлымнарын ялтыратып, атменәр болгар яугирләре килеп чыгар төсле. Тик... тукта! Тарихка юнәлтсәң хәтерне... куркыныч! Идел ярындагы бердәнбер татар авылы... Табигать гүзәл булса да, күңелдә – ШОМ. Идел ятим. Идел буп-буш. Пароходлар йөзми. Корсагына алагаем мал тутырган дәү-дәү баржалар чайкалмый. Юл сабуны сорап, карлыккан тавышка бер-берсен сәламләгән теплоходлар Идел төбенә чумганмы? Төптә дә зәңгәрсу-кара радиацияле ләм белән балык-

---

[1] Руша – кеше тарафыннан утыртылган агачлык, кечкенә урман.

[2] Татарстан Республикасы Югары Ослан районында урнашкан авыл.

лар каберлеге икәнен белмәгәнме әллә алар?[1] Дачабызда ике тәүлек яшәдек, күз карашын ияртеп китәрлек хәрәкәт күрмәдек. Тынлык кадерле кунак булса да, киң Идел өстенең кыргый бушлыгы күңелне телем-телем турый, куркыта. Идел – хәрәкәт! Яшәргә тиеш ул! Ә быел Идел үксез, ятим. Җан бирергә сузылган арык гәүдә. Кызыл Байрактан кайткач, ике көн рәттән Гарәф[2] белән балыкка чыктык – кирәк бит! Идел безнең якта да үксез, караучысыз калган үксез баладай кызганыч. Акчарлаклар юк. Идел утрауларының хуҗасы – сандугач сайрамый. Әле кайчан гына «Куак саен сандугач!» дип сокланып язган идем. Көймәгә утырып барганда, ян-яклардагы яшел утраулардан, уңнан-сулдан, пар-пар челәннәр очып күтәрелә, алар авыр, салмак канатлары белән көймә йөреше уңаена очып иярә торганнар иде. И-и, нинди хозур булган ул чаклар! Моркваш күленнән Олы Иделгә чыга торган тар бугаз өстеннән каршы якның ермачланган текә ярлары, Иделне дулкыннары белән сөендереп, йокыдан уятып үтеп-сүтеп йөргән таудай ак пароходлар, дәү-дәү чуртан баржалар, күңелне әллә кайларга чакырып, өзлексез үтеп, күренеп торалар иде. Теге як яр астына кармак салырга теләгәндә, кара-каршы йөзгән баржаларның, теплоходларның, ындыр табагыдай җәелгән салларның үтеп киткәнен көтеп, чират җиткерә алмыйча зарланыша торган идек. Бүген күзгедәй Идел өстен дулкыннар чатлатмый, көттереп кенә ракеталар узгалый, алар җитез, күз сеңеп өлгергәнне көтмичә, аулак өйдә йоклап калып кинәт сикереп торган үшән егетләр ындыр артлатып ашыккан кебек, тиз-тиз югалалар. Моркваш күленә дулкыннары да кереп җиталмый. Берәүгә дә юл сапмыйча, дулкыннарны постырып басып узган киң-киң саллар кая киттеләр икән? Бушлык, җансызлык. Димәк,

---

[1] Ул елларда гаҗәп куркыныч булып тоелырлык хәл күзәтелде: йөк ташып әрле-бирле агылган поездлар хәрәкәте сирәгәйде, су өстендә дә шул ук хәл күзәтелде. Берничә елдан соң хәрәкәт яңадан артты.– *Н. Гыйләҗева искәрмәсе.*

[2] Гарәфетдин Низаметдин улы Шәрәфетдинов (1929–2011) – журналист, китап бастыру эшлеклесе, 1973–1987 елларда – Татарстан китап нәшрияты директоры. РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1979).

ил хуҗалыгында эшләр кәкәй. Идел илгә хезмәт итми, каңгырып-җылап бушка ага. Иделдә эш сүнгән икән, бу – бетү, бу – ярлылык, хуҗасызлык галәмәте. ШОМ!

Займищеда янәшәбездә тимер юллар сузыла. Андагы җанлылыкка, теңкәгә тигән көне-төне хәрәкәткә күз иярми торган иде. Соңгы атна-ун көндә тимер юллар да парлашып ялга чыктылар. Электровозларны кайдадыр күгәреп бәйдә торган тепловозлар алыштырды, баш очына тагын төтен, сөрем кайтты. Вагоннарның тәгәрмәчләре май сорап чиныйлар. Элек караватка ятсаң, җир тетри, ярлар ишелә, идәннәр исерешеп бии торган иде. Хәзер – юк. Тынлык белән куанасы килгән күңелгә ШОМ бүселеп ята, тел тешләнә. Усал сүзләрне әйтеп котыласы килә, кемгә атап әйтәсене белмәгәнгә, тешләрне тимер койма итәсең дә ироннәрне йомасың.

Әйе, дөньяның бар мәшәкатьләрен, җиһанның сулышын аңлатыр өчен, өч хәрефле бер сүз җитә икән: ШОМ!

Байтактан яңгыр төшкәне юк иде, бүген, шөкер, ат ялыдай юллы-юллы, яшен камчылары сузылышкан баганалы-баганалы болытлар өстерәлеп килеп җиттеләр дә безнең баш очына, казык кагып, тышау салдылар. Сәгать икедә яварга тотынган ташкын кичкә кадәр тоташтан койды. Әле хәзер дә китеп өлгермәгән болыт кибәннәре, мыгыр-мыгыр килеп, һаман шәбәртәләр. Инде кичке сигезләр булып килә. Шәһәр марҗалары явымны, дымны сөйми, алар шәһәрдәге тартмаларына ашыгалар, күлләвекләрнең болганчык күзләрен сытып, лай чәчеп, аллы-артлы поездга чабалар. Җилфердәгән күлмәк итәкләренә күз иярми. Таза балтырларына, сихри тез асларына яшьлекне сагыну ияреп китә. Чап-чап! Мин икенче катта. Маңгаемны суынган пыялаларга терәп, әле бер якка, әле каршы тарафка чыгып, бакчамны күзәтәм. Күбрәк марҗалар чабышкан юл ягына чыгам икән!.. Оялып, читенсенеп, Яхиннар[1] ягына чыктым. Ходәвәндәм, алтмыш бишне тутырып килгәндә, әле һаман күз зинасы кала микәнни?!

Яңгырга сөенергә кирәк тә, булмый. Болыттай кабарынган, болыттай салынган ШОМ, күңелдән агып чыгарга юл таба алмыйча, һаман әйләнә, тулгана, быгырдый. Ага вакыт,

[1] Альберт Гатуф улы Яхин (1931–2010) – язучы, әдәбият галиме. РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1973).

әллә җаннан, әллә тәннән, умырып-умырып, тере ярчыкларны каезлый. Җәйнең иң асыл, иң хозур көннәре ләбаса, сөен, сикер, кинән! Хәлем түзәрлек, шөкер, шикәр авыруым әллә ни сиздерми, авызым кипми, кадерле даруым – букарбаным бар әлегә. Сөенә алмыйм гына бит! Шатлыгымнан да хәзер кара күләгә төшә.

*1992, 5 июль. Иртә*
*Займище*

Verba volant, scripta manent!

Сүзләр оча, язган кала!

Сизелә башлаган корылык үзе бер ШОМ иде. Яңгыр кинәндереп үтте. ШОМ кимемәде. Идел-йортның зәһәр дулкыннарын ияртеп килеп, нинди әче кислоталар, кай заводлардан үтергеч агулар калдырып китте икән бу юлы болытлар, дип, үзем басып торган, улларым, балаларым яшәгән сүзсез җиргә иеләм. Болганып яткан нәни дулкынчыклар чуарланган, чит-читләре күкерттәй сарыланган күлләвекләргә карыйм. Табигатьнең һәр ымыннан, гап-гади үзгәрешләреннән ШОМ көтәсең. Инде безнең уртак өметләр дә үлеп бара бугай. «Надежда умирает последней», – диләр руслар. Әллә бу – соңгы өметләрнең тайпылышымы?.. Гәрчә бүтән сүзләр дә бар! «Noch am Grabe pflanzt er – die Hoffnung auf» – «И на могиле пробиваются ростки надежды», – дигән, киләчәккә өмет белән караучы Фридрих Шиллер[1]. Ышаныргамы? Юк, әлбәттә. Шиллер безнең заманның шушы кадәр өметсез, мәрхәмәтсез, шәфкатьсез булырын бер генә тапкыр да күз алдына китермәгән. Шагыйрь кеше адәми затның дөньядагы иң явыз, тиңдәшсез ерткыч булып үзгәрәчәген белмәгән...

ШОМ коммунистлары, Пушкин шәһәренә җыелып, XXIX съездларын үткәрделәр. «Яңарыш съезды» дип атадылар аны. Исеменә кара: «яңарыш». Әле кайчанрак кына Туфан Миңнуллин: «Мин – коммунист!» – дип күкрәк каккан иде. Яфрак астыннан күпме бөҗәк, ничаклы хаиннар баш калкытып чыгачак әле... Нәни генә үзгәреш башланса да, кан эчәр ком-

[1] Иоһанн Кристоф Фридрих фон Шиллер (1759–1805) – немец язучысы, философ, сәнгать теоретигы, профессор, хәрби табиб.

мунистлар җирне басачак. Фашистлар-шовинистлар да туктаусыз үрчи тора. Илдәге һава, сасы дым аларга ашлама, нур, дым биреп тора. Үрчиләр, үсәләр, калкыналар, борчак сабаклары кебек, бер-берсенә җеп сузалар, укмашалар... Берзаман шул йомшак җепләрне безнең муенга бау итеп салырлармы? Мөмкин. Бик ихтимал. Фашист-коммунист – ике чабата бер кием. Бүгенгә чабата, иртәгә – тевтон рыцарьларының тимер табанлы корыч башмаклары. Илне сытып кына үтәчәкләр. Кеше җаны аяк киеменә ияргән тузан гына лабаса. Кагып төшерәчәкләр... Көне килгәнне көтәләр. Әзерлиләр. Шовинист-фашист коммунистлар ал таңнарның берсендә, сикереп торып, тотаклашып, җитәкләшеп, ирек хәрәкәтенә каршы чыгып басарлар да, Рәсәйне яңадан бер капчыкка тутырып бәйләп, безләрне рәттән суя башларлар әле. Коммунистлар алар фашистлар гына да түгел, аларда мең явызлык, мең шәфкатьсезлек! Бигрәк тә хәзерге шартларда: ил аксаганда, икътисад тилмереп җан биреп ятканда, халык гамь белән ваем эчендә саташып йөргәндә, буш вәгъдәләр эленгән әләмнәрен болгап, мәйданга тагын большевикларның өрәге – коммунистлар калкып чыкса... аңгырайган адәмнәр алар артыннан ияреп чапмас дисеңме? Үпкәлисеңме, юкмы, тарихы заманында берчакта да демократияне татымаган рус халкына бары тик корыч кул, тимер богау вә канэчкеч хакимият кенә төс!

Ельцин[1] [...] – өзеп әйтү әлегә кыен. Шушы арада, буп-буш ямаулы капчыгын селкеп, Мюнхенга – без гасыр буена каһәрләгән капиталистларга теләнергә бара. Горбачёвны[2] шулай бер аркасыннан кагып, сүз белән юатып калганнар иде инде. Хәлсезләнгән, бетәшкән, үләргә йөз тоткан коммунистик режим җимеше Рәсәй калкынырга, җиде сыерны да имеп аякка басарга җыенамы? Һаман-һаман чит илләр хәзинәсенә

---

[1] Борис Николаевич Ельцин (1931–2007) – дәүләт һәм партия эшлеклесе. 1955 елдан – хуҗалык һәм партия эшендә. 1990–1991 елларда – РСФСР Югары Советы Рәисе, 1991–1999 елларда – Россия Федерациясенең беренче президенты.

[2] Михаил Сергеевич Горбачёв (1931–2022) – дәүләт, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе. КПСС Үзәк Комитетының соңгы Генераль секретаре, 1990–1991 елларда – СССР Президенты.

күз тотып рәтләнеп булырмы? Нигә хөкүмәт көрсиләренә урын биләгән рус-улак арасыннан бер акыллы баш, күтәрелеп, «Җитте! Үзебез эш тотып карыйк!» дип оран салмый?! Үз иленңдә үз көнеңне күрерлек акылың калмаган икән, акылны импорт итеп алып кайтып булырмы икән?

Яңгыр, шашып китеп, түбә тишеге аша өйгә үтте, кухня түшәменә сары ашъяулык җәйде. Түбәмне япкан бимитның көче тәмам. Бимитны каерып алып, түбәне шифер белән ябарга кыҗрап йөрдем. Йолдыз Вәгыйзович Курмашев[1], шифер да бирәм, дигән иде – өлгермәдем. Хәзер көчәнергә, иза чигәргә туры киләчәк. Без яшәгән, без җайлашкан заман үтте, хәзерге заманга, бүгенге базар мөнәсәбәтләренә, икътисадка без яраша алмыйбыз. Кияү булсак та, бу туйга түгел инде без. Түбәгә үтеп кергән су – адәм әгъзаларына үтеп кергән рак күзәнәге ул.

Торам да, аптырап, як-ягыма күз ташлыйм: дачаларда басып яшәүчеләр калмады, бик күпләр алдан ук аякларын киенделәр, Казан тирәсе авылларыннан йорт-кура сатып алып, шул нигезләрдә тормышларын дәвам итәләр. Бәрәңге утырталар, кош-корт асрыйлар. Күршем Альберт Яхин Шәледән[2] – җөмһүриятнең бәрәңге патшалыгыннан – 25 сутый җир алды. Шәле бәрәңгесе!.. Ярмалы, коры, күзәнәкләре тирән түгел, чубыргалы бәрәңге. Альберт хәзер дачасына шпион шикелле яшеренеп кенә кайтып керә дә дәшмитынмый чыгып сыза. Икенче күршем Марсель Зарипов та[3], 11 умартасын багып, кайдадыр карурманда качкын булып ята. Көзгә берсе – бәрәңге сәүдәсе, икенчесе чәчәк балы базары ачып җибәрәчәк. Оттымы алар? Откannардыр, мөгаен. Йорт аралаш шул хәл. Зәки белән Мәрьям Ахъяровлар[4]

---

[1] Йолдыз Вәгыйзович Курмашев (1930–2008) – Зәйдәге «Заря» агросәнәгать комплексы җитәкчесе.

[2] Татарстан Республикасының Питрәч районындагы иң зур татар авылы.

[3] Марсель Харисович Зарипов (1931–2017) – язучы, журналист. ТАССРның (1981) һәм РСФСРның (1987) атказанган мәдәният хезмәткәре, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1987).

[4] А. Гыйләҗевнең дача күршеләре.

югалды, Фатыйма апа[1] төтен булып очты. Күпчелек картлар өй саклап шәһәрдә яталар. Тимер ишекләр куйдыралар да өйдән чыкмыйлар. Төн саен зур йортлардагы квартираларның берсен басмый калмыйлар икән. Нибуч, сагаерсың. Адәмдә оят дигән нәрсә бетте. Оят беткәч, адәмдә курку да калмый. Курку калмаган илдә кансызлар үрчи. Фәкыйрьлек, ачлык, белгесез киләчәк моңарчы юаш күренгәннәргә дә усаллык тамыза. Моңарчы дәшми-тынмый йөргәннәр дә билләренә – хәнҗәр, куеннарына алтатар тагып, юлбасар булып китәләр. Моңарчы җинаятьләр төрлелегенә багышланган дәреслекләрдә язылмаган хикмәтле җинаятьләр эшләнә. 53 баланың башына җиткән Чикатило[2] берүзе ни тора! Шул үләтнең судтагы капризларына түзеп торалар бит! 200 мең кеше 10 ел дәвамында эзләгәч кенә таба алдылар ул иблисне. Күпме җан кыйды, күпме адәмнәрне кара хәсрәткә күмде, безнең кесәдән аның өчен күпме акча чыкты! Менә җәй үтеп бара, урманга кергән юк диярлек.

Урман ШОМ оясы. Әлерәк кенә Казан төрмәсеннән 5 явыз качты, рецидивист руслар. Ил күләмендә, яңа амнистиягә ияреп, 60 мең тоткын иреккә чыкты. Амнистия булмасын, димим, үземнең дә аны өзелеп көткән чакларым бар иде. Кем чыга бит, кемнәр кемнәрне азат итәләр! Җәнҗаллы төбәкләрдән качаклар кайта. «Аларның күпчелеге, шул җөмләдән борыны канаган, үч алырга ярсыган кара рус-улак та сыйлы табынлы, тыныч түрле Татарстанны сайлый» дип шөбһәләнеп яза газеталар. Ә качаклар – дөрләп янган учакта очлы башлары белән тырпаеп аркылы-торкылы яткан коры-сары ботаклар алар. Тырпаеп торырлар-торырлар да гөлт итеп кабынырлар.

* * *

Чиләгемә чын көмеш су тутырып, тын иртәдә, сөенә-сөенә, коедан кайтып барам. Каршыма Рәсим Сәйдәшев[3] килә. Якынаюга, буш чиләген төбе белән әйләндерде... Буш чиләк белән очраштырмый, янәсе.

---

[1] А. Гыйләҗевнең дача күршесе.

[2] Андрей Романович Чикатило (1936–1994) – җинаятьче.

[3] А. Гыйләҗевнең дача күршесе.

• «Иске сукыр күнеккән, яңа сукыр дөмеккән»; «Тозсызны күзсез дә күрә».

*1992, 5 июль. Көпә-көндез*
*Займище*

Анда-монда барганда каршыма берәү очрады исә, адымнарымны акрынайтам да уйларымны тәртә арасына кертеп, эшкә кушам: «Йә, җитмешенче яшь белән барасың, күпне күрдең, бел: нинди уйлар асрап яши бу адәм? Йөз-кыяфәтен өйрән, әйтеп бир!» Адәм балалары эш күплектән иза чиксәләр дә, табигый буларак, аларның ара-тирә буш вакытлары да кала, кеше буш вакытына, асылда, үзе хуҗа. Тәүлек дәвамында адәм балаларының япа-ялгыз калган чаклары да була. Ялгызлык – уй ул. Йә, әйт: нинди тәмамланмаган уйлар аларның баш мие шарларында тузгый соң? Элек, моннан өч-дүрт ел элек тә, мин уйсыз бер минут та яши алмый идем. Елның кайсы фасылында, көннең кайсы бүлемтегендә булмасын, төрледән-төрле уйлар, шакып-нитеп тормыйча, чиксез озын җеп булып башыма уралалар да, ми шарларым йомгак булып авыраялар иде. Берьюлы өч-дүрт әсәр тирәсендә була иде кайнар уйларым. Хәтерлим, иртә-кич Переделкиноның аулак сукмакларын адымнарым белән үлчәгәндә, йорт кысасы мәшәкатьләре, Казан тормышының бимазалы ыгы-зыгылары чак кына онытылып торганда, һәр яңа адымым аңыма нидер тартып китерә, хатирәләр казанында кайнап онытыла язган кадерле истәлекләрне уятып чыгара да, язылачак әсәрләремнең берсенә җилемләп беркетеп куя торган иде. Урманның һәр борылышында мине ачыш, һәр куак артында көтелмәгән кадерле уйлар өермәсе сагалап тора иде. Япа-ялгызлык һәм зарыктырган тынлык миңа уйдан канат тага иде. Оча идем мин уй-фикернең ташыган дәрьялары өстеннән! Урынга ятып өлгермисең, ми үзенә хас адымнар белән уйны йөгертә башлый, каулый, ашыктыра, уем үтеп кермәгән дөньяда почмак юк, хәтер ачык, аек, уй җебен нинди давыллар кагылганда да өзми саклый ала, азагына кадәр дилбегәне кулдан ычкындырмый. Күпме әсәрләр әнә шул уйлар өермәсе уртасында туган вакыйгалар нәтиҗәсендә дөнья күрде.

Арып-талып ятсам да, мин ял итмим, акыл үзеннән-үзе уй тегермәнен әйләндерә, уйның җылы оны мөшкәдән өзлексез ага, тонна-тонна фикерләрем, акылның кыл иләге аша каткат үтеп, чүп-чардан арына... Ниһаять, кат-кат иләгәннән соң гына, акылга ятышлы, йогышлы саналган уй-нәтиҗәләрем әсәр юллары булып иркен тезеләләр иде. Минем берчакта да уйлар торгынлыгына әсир төшеп, каләм очы чәйнәп тинтерәп утырганым булмады. Уйлар күңелемнең давыллы диңгезендә ярадылар, шунда туып, шунда ныгыдылар, берчакта да онытылмадылар. И хәтеремнең көчле, әтрафлы чаклары! Күңелемнең күзәнәкләренә килгән фикерләрнең сакчысы – аек хәтерем! Мин уемның ял иткәнен, фикер сугыш-көрәшләреннән арынганын хәтерләмим. Бары тик бер урында – Идел тугайларында балык тотканда, су асты дөньясы белән нәзек җеп аша якыннан аралашканда гына, вакытвакыт онытылып, җаным күбәләк булып очканда, мин табигатьнең бер кисәкчәсенә әйләнгәли торган идем. Бүтәнчә уй шарламасының тынганы юк, ул гаярь вулкан кратеры сыман кайный, дөберди, ыргыла, вулкан кратерына сыеша алмыйча, тышка бәреп чыга. Әсәрләргә әзерлек туктаусыз дәвам итә, яшисең, йөрисең, сак күз һәрчак маңгай астында, дөньяның минутларын җыеп ала, чагыштыра, туплый, барлый, хәтернең вак күзәнәкләре, җитмәсә, уйларның эресен-вагын сөзә бара, артык-портыкларыннан арына, яңа тәэсирләргә, туачак уйларга урын әзерли. Кино карыйсың, телевизор алдында утырасың, күз алдында әллә нинди хәлләр туып җимерелә, ә аң, уй, фикер һаман үзенекен үти, ми шарлары, алга тәгәрәп, үз сюжетыңны алга сөрәләр, уең өзелмәс берничә юнәлештә үзенә юл сала. Тормышта ишеткән мәгънәле вә гыйбрәтле вакыйгаларны хәтер тозагына төшерәсең дә, тамга салып, аларны алдагы эшләрнең нигезенә чәпәп куясың. Әһә, дисең, бу гыйбрәтле сүз фәлән әсәргә кулай булачак икән... Әһә, дисең, адәмнең бу гамәле төгән әсәрнең агышына ипләнә икән, шуңа ятып тора... Болар, асылда, әдип акылы белән үзеннән-үзе эшләнә. Әдипнең акылы шундый гаҗәп, могҗизалы орган ул, аның хәрәкәттән туктаганы юк, эшли-эшли, ул ял итмәскә күнеккән, күзне күрсен өчен көчләргә кирәк булмаган шикелле, акылны да тәртә арасы-

на кертеп чыбыркыларга кирәкми. Әдип акылы – туктаусыз шаулап ага торган ут елгасы ул. Күп вакыт күргәннәргә игътибар да итмәгән кебек буласың, үтә-китә, мәгәр әдипләргә генә хас акыл үзенекен эшли: уй-тойгыларны хәрәкәткә китереп, күргәннәрдән иң кыйммәтлесен сайлап ала, беркетә, хәтердә ныгыта. Һәм һич көтмәгән мизгелләрдә, эш кызып барганда, иң кирәк чагында гына, әдипнең яшерен акылы хәтер киштәсеннән зарури хәзинәне алып бирә. Әдәбият эше,– асылда, яшерен, астагы акыл хәзинәсенә ия булу ул. Әгәр шундый, синең ихтыяр көченә баш бирмичә тупланган яшертен, астагы акыл хәзинәң юк икән, син – көнлекче! Син, колак артың кашып, төчкереп-йөткереп, хатыныңны сүгеп, балаларыңа ырлап, илһам көтеп утырасың. «Йа Ходa, бир мәдәт!» Ә илһам килми, илһам яшерен, астагы акылның зурлыгыннан, аның заманча тере булуыннан тора. Әдип – тырыш, мәңге ял белмәс бал корты ул. Әдипнең гомере – яз, җәй. Үтә кыска. Шул кыска җәйдә ул кәрәзләренә мул табыш җыеп калырга тиеш. Мин моңарчы уйсыз яшәмәдем. Уй белән тотаклашып яшәү әдип өчен иҗади бәхет китерә. Синең астагы яшерен акылың бай икән, син бәхетле. Син үзең сөйгән, җаныңны җылыткан хезмәт белән гомереңне уздырасың. Син бай икәнсең, уең туктаусыз хәрәкәтләнә дигән сүз. Акылдан тамып ак кәгазьгә төшкән уйны хисләр бизи, аны кирәк төсләргә мана. Әдәбият табигатьнең үзе сыман мең төсле ул, чөнки чын әдип – сихерче рәссам.

Ни үкенеч, бәхетле җәй томырылып үтә китә икән. Иртәкичләрем хәзер уйсыз уза диярлек. Нәтиҗәле уйларымның тамыры корыды. Уйсыз яшим димим, уйларым бар, тик алар миңа канат куя алмый, уйларым адымны акрынайталар, гәүдәмне җиргә сөйриләр. Артка борылып-борылып карыйм, күздә – кара томан, акылда – өермәдәй ШОМ. Ымсынып алга текәләм – анда да кара пәрдә. Пәрдә артында ни – белә алмыйм, сизгерлегем, үткенлегем юк. Аргамакларым, йөгерек чабышкыларым үткән гомер сукмакларында таралыпюгалып беттеме?! Уй дуамаллыгына ия булмаган адәм уллары ничек яши икән? Уйсызлар буламы? Мин, трамвайга кереп басуга, кемнедер сайлап алам да, башыннан аягынача җентекләп, туктый-туктый күзәтәм. Газапланам: ни уйлый бу

кеше? Нинди уйлар йөртә аны? Арада угрылар, җан кыючылар, фахишләр, мөртәтләр дә бар ич. Бар гынамы сиңа, андыйлар – бүгенге көн җимешләре, күп алар... Алар күңеленә уй ничек иңә? Кем кодрәте белән? Җәйге таңнарда, сандугач моңын тыңлаганда, алар нинди уйда булалар? Балаларын ничек, нинди өметләр белән иркәлиләр? Күкрәкләренә җылы диңгез дулкыннары үрмәләгәндә, алар нинди уйда коеналар икән? Сөйгәннәренең мәхәббәт җылысын тойганда, алар кем булып кала? Табигать биргән рәвешләренә әйләнеп кайта алалармы? Әллә аларның иркәләү алымнары бүтәнчәме? Уйларның чиге, үлчәве юк, ул – канатлы тулпар, ул – дошманнарын бер селтәнүдә кырып салучы Салсал батыр[1]... Тик угрыга уйның мондый гаҗәеп сыйфатлары кирәкме икән? Табигатьнең адәм уен чикли торган бер-бер хикмәте бардыр. Менә хәзер, гомеремнең салкынаеп калган көзендә, талпынып-талпынып аяк өстендә калырга, тәкмәрләп китмәскә тырышканда, тере уй чыганагын каян алыйм? Кемгә таянсыннар уйларым, кемгә?.. Бу – максат кынамы?!

*1992, 6 июль*
*Займище*

Ялгызлык – зарыктырып килгән рәхәтлек ул... Бер үк вакытта, ара-тирә, ялгызлык шомлы уйлар үрчегән упкынга тотып чөя! Шөкер, димен, бөтен кеше дә минем хәлдә яшәми, миндәй уйламый, алар офыгын салкын божра бу-ып куймагандыр... Салават күперендә кап-кара, йөнтәс дуга күрмиләрдер алар! Шунысы шөкер! Әле бүгенге ишелепҗимерелеп барган җәмгыятьтә бәхет татый торган яшьләр бардыр, кеше күңеленең иң югары эсселеккә ирешеп кайнаган ноктасы – сөю-мәхәббәт бардыр. Шиллер әйткәндәй, каберстанда да өмет шытымнарын абайлый алырлык якты күзләр бетмәгәндер. Хак, сизәм, таныйм бүген, мине белгән шомлы уйлар да бардыр! Мәсәлән, туа-туышка үземне язучы итеп тойдым. Тора-бара үземне татар әдәбиятында яңа сүз әйтә алырлык олы талант иясе дип исәпләп йөрттем. Хата булган! Рәхмәт Тәңрегә, ул миңа талантны кызганмыйча, мул итеп каерып биргән. Ләкин минем акыл үсешем заманнан

[1] Салсал батыр – дастан герое, алып.

һәрчак артта килде. Нәтиҗәдә мин «поздно созрел». Дөньяның дүрт ягын, милләтне, милләт язмышында әдип тоткан урынны бик тә үземчә, тар вә ялгыш аңлаганмын. Мин фәкыйрь «Милләт бербөтен ул. Ул бердәм булырга тиеш. Тарих милләтне туплый, аның төрледән-төрле катламнарын калыплый, ныгыта» дип инанып яшәдем. Янәсе, милли әдип аның тоткасы, әдип – вәкил, ул милләтне борчыган мәсьәләләргә җавапны тизрәк таба белә, милләттәшләрен үз артыннан өнди, ияртә дә, җитәкли дә... Иң мөһиме, әдип белән милләт арасында берлек, бердәмлек булырга тиеш, янәсе, табигать әдипнең урынын таң яралганнан ук билгеләп куйган. Һәм мин, янәсе, табигать көтеп алган ир-егет, татарны алга илтүчеләрнең берсе булам... Милләттәшләре аңа рәхмәтле булырга тиеш, аны аңларга, ниндидер бер дәрәҗәдә аңа табынырга да бурычлы, дип исәпли идем... «Җиз кыңгырау», «Киек Каз Юлы», «Әңгер-меңгер», «Югалган көн» пьесаларында мин әнә шул юнәлештәрәк тырышып маташкан идем. Ялгышканмын! Томана зирәк булганмын! Шыр тиле! Кырык ахмак! Алты-биш Сапый икәнмен! Утыз-кырык ел күпме көч, егәр сарыф иткәннән соң гына, мин үз хезмәтемнең бәясен аңладым шикелле.

Чын әдип белән милләт арасы берчакта да тыгыз була алмый. Милләт ул – адәмнәр төркеме. Кемнәр генә юк ул төркемдә! Белем җәһәтеннән булсын, аерым кешеләр берберсеннән нык еракта һәм капма-каршы яссылыкларда гомер кичәләр. Акыл төзелеше ягыннан да ерак алар, уй-фикер сөреше җәһәтеннән дә, яшәгән саен, бер-берләреннән аерыла, читләшә, ерагая баралар. Кешеләр төркемен бербөтен итеп илдә куелган законнар гына яшәтә. Ә закон-кануннарга буйсынып кына бер өергә тупланган җан ияләрен ялгыз әдип куенына сеңдерә вә сыйдыра аламы? Күпме тере зат сыя бер әдип куенына? Фи-и-и... Кыскасы, язучыны, үз итеп, милләтнең бик санаулы, нәни генә төркеме кабул итә ала. Чикләнгән, тар төркеме генә! Җиде миллион татар, дибез... Шул саннан күпме кеше Әмирхан Еникине белә? Нурихан-ны? Мөхәммәтне? Мине?.. Күпчелек әдәбиятны укымый, аңа төкереп кенә карый, әдип сүзенең зарурлыгын тоймый, ул әдәби сүзгә бөтенләй мохтаҗ түгел! Хәзерге заманда бигрәк

тә. Адәмнең сәнгатькә, әдәбиятка булырга тиешле тойгыларын телевидение йомарлап тота, кинотеатрлар үз тирәсенә туплый, хоккей чәкәләшләре йотып ала, футбол бәрелешләре. Тормышны – бөтен, үзләрен бәхетле итеп тотар өчен, мең-миллионнарга әнә шул кайнар ярышлар, бокс сугышлары, баскетболистларның тиргә чумып ыргылулары тәмам җитә! Америка профессионалларының темпераментлы ярышларын юкка гына күрсәтә башладылармы бездә?.. Өер-өерләр бер-берсенә кызып-кызып ташлана, берәүләре өскә чыга, бүтәннәр аста яньчелеп кала. Тамашачы һәрчак җиңүчеләр ягында, тамаша караганда, аның да каны кайнарлана, пары җитмәсә, ул таш өстенә бер-ике чәркә аракыны кушып җибәрә... һәм адәм оҗмах бакчаларына күчә! Нәни генә, орчык башы хәтле генә җаны тантана итә! Футбол, хоккейлар алар – тоташ гипноз, өерләрне алдау... үзем дә, зәңгәр экран-тәрәзәчектән сатлык политикларны, буш үгетчеләрне тыңлап утыруга караганда, футбол-хоккейларны өстенрәк күрәм. Әдәбият уку – көч, игътибар, дикъкать сорый. Әсәр укыганда, кеше акыл көчен генә түгел, физик көч тә сарыф итәргә тиеш... Ә адәмнәрнең көче, ихтыяры китап укырга калмый, алар аны арзанлы бәрелешләргә бирә-бирә сарыф итеп бетерәләр. Күптән түгел генә үзәк газеталарның берсе Толстой, Тургенев, Гончаров китапларының китапханә киштәләрендә еллар буе укылмыйча, әче тузанга манчылып ятуларын әрнеп язып чыккан иде. Безнең китаплар да ята. Ятачак. Егерме ел эчендә басылып чыккан әдәби материалның нибарысы ике проценты гына алдагы елларга уза. Бу – саналган, үлчәнгән хакыйкать. Без ыштансыз һәм мәгънәсез татарлар гына, шул аяусыз канунны санга сукмыйча, еллар өйгән бөтен черек чүп-чарны – Гариф Галиев[1], Гариф Гобәй, Нәби Дәүли[2], Идрис Туктар[3] һ.б. китапларын исемлектән төшереп калдырмаска маташып, тишек капчыкларыбызны иңнән иңгә күчерә-күчерә, киләчәккә сөйрибез. Көлке! Сафсата! Әдип язмыш билгеләгән бер чорда үзенә заман-

[1] Гариф Закир улы Галиев (1903–1985) – язучы.

[2] Нәбиулла Хәсән улы Дәүләтшин (Миндубаев, 1910–1989) – язучы, публицист.

[3] Идрис Ильяс улы Туктаров (1896–1992) – язучы.

даш булган милләттәшләренә хуҗа була алмый, алар, сирәк-мирәк аралашсалар да, берчакта да бер уйда, бер фикердә була алмыйлар. Әдип, нинди бөек булса да, үз чордашларын кабул итеп бетерә алмый. Ул нидер чамалый, нидер сизә, тоя, бәлки, дөрес фикер йөрткән чаклары да буладыр, әмма әдипне бары тик киләчәк буын вәкилләре генә, анда да тар мохит вәкилләре, белгечләр, намусы саф кала алган әдәбиятчылар гына тулаем аңлый вә аңлата алачак. Киләчәк буын дулкыны әдипне кабул итәме-юкмы – анысы да әлегә табышмак булып кала. Шакир Мөхәммәдев[1], Мәхмүт Галәүләр әдәбиятыбызда үз эзләрен калдырганнар. Кабул итәме аны бүгенге татар? Ай-һай. Без, бик тырышып, татарга Галимҗан Ибраһимовны сеңдерергә маташтык, барып чыкмады. Менә Гаяз Исхакый[2] кайтты, дип сөенештек. Валлаһи, бөек язучы, олы әдип! «Зиндан»[3] дип аталган затлы китабы чыкты. Сатылмыйча ята. Нуриханның «Сызгыра торган уклар»ын[4] алалар, чөнки Нурихан Гаяз Исхакыйдан талантлырак. Әле Әмирханның, Вакыйф Нуруллинның томнары да сатылып бетмәгән. Замандашларын да укымый бүген татар, диде үткән пәнҗешәмбедә Фәрваз[5], миңа нидер ишарәләп, нидер кисәтеп. «Томнарың чыкса да сатылмый ятар!» дип тынычландырып, алдан әзерләп куюы булдымы?..

Кайчакта искиткеч хәлләргә юлыгасың. Гап-гади, әмма үтә тормышчан язмышларны, һәркемгә якын, аңлаешлы һәм тәэсирле сюжетка корып төшерелгән 300 серияле «Байлар да җылый икән»[6] исемле ерак Мексика фильмын Казанның һәм авылларның яше-карты, русы-татары егыла-егыла, җылый-җылый карый... Кытайда да аны миллиард кеше караган, диләр... Әгәр Кытайда ике миллиард кеше яшәсә, ике мил-

---

[1] Шакир Мөхәммәдев (1865–1923) – язучы, мәгърифәтче, журналист.

[2] Мөхәммәтгаяз Гыйлаҗетдин улы Исхакый (1878–1954) – язучы, журналист, сәясәтче, татар милли азатлык хәрәкәте эшлеклесе.

[3] Г. Исхакый романы (1906–1907).

[4] Н. Фәттах романы (1977–1985).

[5] Фәрваз Мөхәммәдулла улы Миңнуллин (1934–1994).

[6] Мексика телесериалы (1979, режиссёрлары – Фернандо Чакон, Рафаэль Банкельс).

лиарды да карар иде. Аңласаң аңла, теләсә ничек кабул ит. Мин әдәбиятыбыз халыкка битараф булган кебек, халык та әдәбиятына битараф дип өзгәләнәм. Ә монда... Шәһәр урамнары тына, адәмнәр Марианна, Луис Альберто белән очрашу өчен эшләрен ташлап качалар, кибетчеләр, «Санитарный час» дигән ялган такта элеп, арткы аулак бүлмәләргә телевизор каршысына тезеләләр. Сүзләр юк, адәмнәрне күз яше берләштерә... Безнең шундый җитәкләүче көчебез, иманнарыбызны бер итә торган әсәребез бармы? Татарны мең ел яшәтә алган гигант «Йосыф китабы»ның[1] да бүген кыйммәте, көче, туплау хикмәте сизелми. «Идегәй»не[2] күпме кеше укып кабул итте икән? Бүген дөнья кодрәте футбол кулында. Әлерәк кенә футбол буенча Европа беренчелегенә ярышлар булып узды. Нәни генә Дания футболчылары, крестьян кыяфәтле егетләр, мәшһүр спорт иле алманлыларны таптап уздылар. Данияда ул җиңү сәгатьләрендә ни булганын күз алдына китерү кыен түгел!

Милләтне мәгълүм бер дәрәҗәдә атаклы шәхесләр әсир итә ала.

*1992, 10 июль*
*Займище*

Дачада. Ялгызмын.

Усалланган табигать татар җиренә ыжгырып каныкты: кылган хаталарыбыз, ялгыш, гөнаһлы гамәлләребез өчен тәмам үчекте, айлар буе байтак төбәкләрдә тамчы яңгыр төшмәде, кояш «мә сезгә!» дигәндәй кыздырды, болай да хәсрәткә уралып туган таңнарны дәһшәтле мизгелләргә әйләндерде. Арыш башаклары суырылды, өскә үрләргә өметләнгән бодай кырлары пәҗеп җиргә иңде, күләгә эзләп, бер-берсенә йомшак кулларын сузган нәфис борчак тоҗымнары, җиңеләп, яргаланган җиргә егылдылар. Бәрәңге сабакларына алка булып асылынган әмрикән коңгызлары, тәлгәш-тәлгәш оешып, туй итүдән туктамады... Ниһаять, яңгыр җиргә түгел, адәм улларының коргаксыган күңелләренә яуды, бар тереклек, газ-төтен-сөремнән арынып, киң итеп бер сулап куйды.

[1] Кол Гали әсәре.

[2] Татар халкының тарихи героик-эпик шигъри дастаны.

«Татар җиренә бу явыз хикмәтләрне ярсыган рус җибәрә... Теләделәр – әрмәннәрдә җир тетрәттеләр... Теләделәр – Карабах халыкларына сугыш сулышы өрделәр. Мәскәүнең кулы бөтен дөньяны богауларга барып җитә. Менә безне корылык белән җәфалыйлар, былтыр иген-тару өлгергәндә, бәрәңге алганда, яңгыр болытларын Татарстан күгенә бәйләп куеп, җанны талаганнар иде», – дип зарлана бериш халык. Ышанмас та идек, валлаһи! Болытларын гына күтәрелеп кара: җәйге, июль болытларымы болар?! Җәһәннәмнән кубарылган албастылар, иблисләр түгелме әллә?! Кояшның мәрхәмәте беткәнен, озон катлавы юкарып, җиргә зәһәр, үтергеч уклар яуганын беләидек инде. Хәзер «кислород ачлыгы» вәгъдә итәләр. Гайрәтле Мәскәү, бик теләсә, безне кислородсыз да калдырыр! Бауның башы Макашов[1], Жириновскийлар[2] кулында, алар муенга салынган муенчакны тартып кысарга да күп сорамаслар.

Бүген иртәнге биштә торып чыксам, йөзеннән нур качкан Гарәф Шәрәфетдинов каршыма килә. «Афәт бу, чираттагы каргыш!» – дип, күккә ишарәли. Татар гына шигәя дисәк, аргы башта юл уртасында рус Трубаевны[3] очраттык. «Афәт бу, ей богу, табигать безгә бәла арты бәласен җибәрә!» – дип, ул да сукрана. Кып-кызыл большевик, элеккеге райком секретаре, ГКЧП калкып чыгуга, сүзләре тамак төбеннән генә горгылдап чыккан бәндә.

Гарәф белән Гудковлар дачасы артына, Идел ярына барып бастык. Манза-а-ра! Ахырзаман! Килбәтсез иблисләр атланган кара яллы дулкыннар, шашып-ыргылып, безнең зәгыйфь аяк очларына килеп җитеп, безне упкынга тарталар. Болытлар аръяктагы тәбәнәк тауларга тия-тия шуыша, агач ботакларына уралып ял итә. Баксаң, хәлдән тайган болытлар безнең кетеки тауларга да төшеп җитә ала икән. Әйтәм ич, Идел аръягындагы себерке-урманнарга болытларның

---

[1] Альберт Михайлович Макашов (1938) – совет хәрби җитәкчесе, отставкадагы генерал-полковник.

[2] Владимир Вольфович Жириновский (1946–2022) – рус совет сәясәт эшлеклесе, Дәүләт Думасы Рәисе урынбасары (2000–2011), Россия либераль-демократик партиясенә (ЛДПР) нигез салучы.

[3] А. Гыйләҗевнең дача күршесе.

иләмсезе, аклы-каралысы уралган. Һәр агач, һәр тырма-ботак кына түгел, җиргә сыпылып яткан үләннәр дә болытларга якорь булганнар. Болытлары аяк астыннан ук шуыша, үрмәли, тәгәри. Җил котсыз! Кай яктан исеп, кая барганын белеп тә булмый. Арыган җил, аның агачларга кунып ял итәсе килә, агач ботаклары әз генә тынып торалар да, иңнәрен кагып, болытларны өерләп куа башлыйлар. Җир шарында уй-фикер тотынып торырлык нокта калмаган кебек, җир өстендә җилләргә ял бирерлек әмәл дә калмаган. Әллә шуңа алар, тыела алмыйча, офык артыннан безгә туктаусыз болыт кәрваннары ташый. Рус иленә каһәре төшкән Ходайның да кодрәте калмадымы әллә? Тфү, тфү, көфер сүз сөйлим түгелме? Сөйләү түгел, акырып-бакырып артың белән киртә җимерсәң дә, бүген син каһарман түгел. Киресенчә, табигать котырынганда, чынлап торып дулаганда, мактанчык җир уллары, бәләкәйләнеп, утырган эт биеклеге генә калалар. Күкрәкләре иске тальян күреге сыман гыжылдый, тезләре күчәре ашалган тәгәрмәч кебек кылдый-былдый килә, йөнтәс борын тишекләреннән һава түгел, зәһәр төтен сызгырып чыга. Язмыш үрмәкүчләре тирәнәйткән маңгай җыерчыкларына ачы тир кереп тула.

Тирләтә дөнья! Сикертә дөнья!

Атна буе дачадагы нәни чоланымда качып ятып (икенче катта аулак, җып-җылы бүлмәчегемне әйтәм!), тәүлекләрне кардай йомарлап артка ыргыта тордым... Эш тотып булмады, иске журналларны актардым, хәтта чишелмәгән кроссвордларны чишәргә маташтым. Искеләр янына яңа журналлар өстәлде: «Казан утлары», «Новый мир»ның 6 нчы саннары килде. Күптәннән болай рәхәт кичереп, һәр юл сызыгыннан мәгънә табып, әдәби әсәр укыганым юк иде. «Новый мир» – мин утыз-утыз биш ел дәвамында өйгә алдырып укый торган журналым. Мин гомерем буе бу журналның әдәби әсәрләрен генә түгел, публицистикасын да, фәнни мәкаләләрне дә күздән кичерергә тырыша идем. Ю. Казаков, П. Нилин[1], Ф. Абрамов[2] (соңгы мәкаләсендә М. Мәһдиев аны хаклы

[1] Павел Филиппович Нилин (Данилин, 1908–1981) – рус совет язучысы, сценарист. Сталин премиясе лауреаты (1941).

[2] Фёдор Александрович Абрамов (1920–1983) – рус совет язу-

рәвештә элеп алып селкеп салды!), Ал. Солженицын, Влад. Войнович[1], Ал. Твардовский, Виктор Астафьев[2], В. Гроссман иҗатлары белән мин беренче чиратта шушы журнал аша таныштым. Хыялым шушы журналда берәр әсәр бастырырлык дәрәҗәгә җитү иде. Әхмәт Ерикәйдән[3] бүтән татар язучысы журналга менеп җитә алдымы икән? Хәтерләмим. «Новый мир» журналы һәрвакыт әдәбиятка кан өсти торды, кыен чакларда да Войновичларга, Синявскийларга көч вә куәт өстәп яшәде. Соңгы вакытларда да анда ара-тирә искиткеч кызыклы мәкаләләр басыла торды. Онытканмын, заманында А. Побожийның[4] «Мёртвая дорога»[5] исемле әсәре миңа искиткеч көчле тәэсир ясап, Себер якларында, Салихард-Лабитнанги тирәләрендә йөрткән иде[6]. Быелгы журналның 6 нчы санында басылган М. Конисскаяның[7] «Злые годы»[8] дип аталган хатирәләрен гаять зур кызыксыну белән укыдым. Конисская әдип түгел, әмма төрле яктан әзерлекле, яшьтән үк затлы һәм максатлы тәрбия алган, күпне укыган, югары дәрәҗәдәге зыялылар белән тыгыз аралашкан, зыялыларның бәрәкәтле тәрбиясен күргән ханым. Ул, һич тарсынмыйча, үзе кичергәннәрне нигез итеп алып, зыялыларны һәм мокытларны янәшә куеп, төрле тарихи шартларда чагыштырып карый һәм мең төрле тормыш мисаллары яктылыгында зыялының (биредә сүз чын зыялы турында гына бара!) мокытлардан һич бәхәссез мең баскычка югары булуын үзе татыган газаплы тормыш күренешләре белән дәлилли ала. Без бит – кулда җимерү әләмнәре тотып кына яшәгән түбән зат-

---

чысы, әдәбият белгече, публицист.

[1] Владимир Николаевич Войнович (1932–2018) – рус язучысы. Россия Федерациясе Дәүләт премиясе лауреаты (2000).

[2] Виктор Петрович Астафьев (1924–2001) – рус язучысы. СССРның (1978, 1991) һәм РСФСРның (1975, 1995, 2003) Дәүләт премияләре лауреаты.

[3] Әхмәт Фазыл улы Ерикеев (1902–1967) – шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе.

[4] Александр Побожий, «Үле юл»ның инженеры, проект авторы.

[5] А. Побожий әсәре (1964).

[6] Новый мир.– 1964.– № 8.

[7] Мария Юрьевна Конисская.

[8] М. Конисская мемуарлары (1992).

лар. Рәсәйнең шигаре: «Сначала до основания разрушим... а затем!»[1] Октябрь җимерелүләреннән соң Ленин илдән ике миллион ярым зыялыны чит илләргә сөрә. Кайбер мәгълүматларга караганда, октябрьдән соң 4 миллион кеше илдән качты, дигән сүзләр дә бар. Утызынчы-кырыгынчы елларда зыялыларны турапмы-турыйлар, кулы ак булганы өчен генә дә күпме зыялыларның башы киселә! Хакимиятнең бөтен дәрәҗәләренә акылсызлар, ярты җүләрләр, кабакбашлар, идиотлар килә. Күн ыштан, күн кием кигән, маузер тоткан кемсә, шыр тиле булса да, хакимияткә үрләде. Дурак дуракны ярата. Бу – аксиома. Дурак акыллыны үз түгәрәгенә якын да китерми. Акылсызлар тиз-тиз үз ишләрен табалар һәм кулга-кул тоташалар. Сатлык җаннар, хаиннәр, мокытлар (без аларны, «бөтендөнья пролетарийлары» дип атап, берләшергә чакырдык. Канлы октябрь әләме астына басканнарны илдән талап алынган алтын белән күмдек!). Егерменче гасыр кешелек дөньясының уңай геннарын бетереп, алардан Шариковлар[2], шакаллар өере тудырды. Һәм шундыйларны кызыл почмакка төре итеп күтәрдек. Ныклап уйласаң, әнә шул мокытлар сыйныфы вәкилләрен көнгә чыгарган әсәрләр татар әдәбиятында да бардыр. Уйларга кирәк. Ләкин безнең әдәбиятыбызның үзәгендә һәрвакыт шомарткан, таслаган һәм алга манган Мокытлар һәм Мокытихалар торды. Конисская – әдәбият вәкиле түгел, дип кабатлап әйтәм, әдәби укуы да булмаган, әмма аңа Ходай күпне ышанып тапшырган һәм ялгышмаган.

Без һәр әсәрдән – зурмы ул, кечкенәме – әдәбият кануннарына буйсынуны таләп итәбез, беренче чиратта ныклы сюжетлы әсәрләргә генә ышаныч белдерәбез. Бу әсәр әдәбият законнарыннан күрәләтә качып, тормышның эчке-тышкы үз кануннарына буйсынып иҗат ителгән. Мокыт – русмы ул, немецмы, полякмы – барыбер мокыт, ул надан, надан икән – тупас, тупас икән – явыз. Мокытның талау, үчегү, көчләү, урлашу инстинктлары гына үскән, ул – ярым кыргый, ярым дивана рухы белән кол. Зыялылар исә, күңел югарылыгын, рухи сафлыкны, җаннарында ныгыган мәрхәмәт-шәфкатьлелекне

[1] «Интернационал» гимны текстыннан.

[2] М. Булгаковның «Собачье сердце» (1925) повесте персонажы.

гадəттəн тыш кыен хəллəрдə дə җуймыйча саклыйлар, аны бикләп, яшереп тотмыйлар, үз ишләренә, үзен кабул иткән, аңлаган затларга мөмкин кадәр яхшылык, игелек күрсәтергә тырышалар. Немецларның – мокыт-фашистларның – ниләр кыланганын без хәзер тулаем беләбез инде! Мин Хатыньны да барып карадым. «Мы из огненной деревни»[1] китабы да күңелләргә кереп калган. «Иди и смотри»[2] киносы күренешләре дә күз алдымда. Бөек белорус Василь Быковның повестьларын хәзер дә кат-кат укыйм. Бигрәк тә «Сотников»ны[3] яратам. Хәзер генә аңладым, ул әсәрдә дә тартыш зыялы Сотников белән мокыт Рыбак арасында бара ич!

Конисская без моңарчы кабул иткән, күнеккән штамплардан читкәрәк китә, ул тасвирлаган немецлар бүтәнчәрәк инде! Дәһшәтле, рәхимсез сугыш мәйданнарында немец милләте вәкилләре төрлечә булганнар. Төрле аң дәрәҗәләре белән килеп кергәннәр, һәм бу төрлелек иң авыр, катлаулы чарпалышларда да сакланып калган. Безнең лагерьларда тоткыннар төрле-төрле түгел идемени?.. Мин юкка гына зыялы яһүдләргә, русның акыллы вәкилләре архитектор Уклейнга[4], казачий генерал улы Сидоринга[5], шагыйрь Сергей Сергеевич Козлов-Куманскийга[6] тартылдыммы? Үземнең егерме биш еллык «юбилеем»ны билгеләгәндә, өстәлем тирәсендә шул зыялы затлар һәм немец дустым Һайнц Бём[7] утырмадымы? Немецның зыялы уллары үзләренең кешелек сыйфатларын берчакта да югалтып бетермәгәннәр. Әйе, явыз диктатор режимы елларында алар сагайганнар, рәхим-шәфкать нурларын алар курка-курка гына күрсәтә торган булганнар. Сталин чорында Рәсәйдәге һәр өч кешенең икесе теге яки бу күләмдә МГБ-КГБ хезмәтләренә ярдәм итеп торганда,

[1] А. Адамович китабы (1979).

[2] Нәфис фильм (1985, режиссёры – Элем Климов).

[3] В. Быков повесте (1970).

[4] Архитектор, А. Гыйләҗев белән лагерьда утырган тоткын.

[5] А. Гыйләҗев белән лагерьда утырган тоткын, казаклар генералы малае.

[6] Сергей Сергеевич Козлов-Куманский (1920–1987) – рус язучысы, журналист, 1945 елда, «халык дошманы» дип, төрмәгә утыртыла, А. Гыйләҗев белән бер лагерьда була.

[7] А. Гыйләҗев белән лагерьда утырган немец кешесе.

кешенең эчке дөньясы имгәнмичә калмаган, әлбәттә. Хәрби киемнәргә төренгән зыялы немецлар рәссам, ике нәни бала әнкәсе Конисскаяны бүтәннәрдән бик тиз аерып күргәннәр. Гаилә, балаларга мөнәсәбәт — зыялыларның төп төсмерләреннән берсе ул. Конисская зыялы булуы белән бик күпләрдән аерылып тора, һәм аның шушы югары сыйфатын, затлылыгын немецның затлы офицерлары, солдатлары да бәяли беләләр. Җиңүчеләр — совет солдатлары да бер казанда быгырдаган тары ярмалары түгел автор өчен! Алар арасында да зыялыларны очратырга була. Ләкин күпчелек — соры мокытлар өере. Германиягә барып кергәч, ни генә кыланмый совет солдаты! Көчли, талый, урлый, җимерә. «Җиңүчегә ни кыланса, шул килешә!» дигән әхлак кагыйдәсе совет солдатларын боза, алардагы хайвани инстинктларны котырта. Халкыбызга тупаслык, җаһиллек, караклык-бурлык, имансызлык каян килә, дип, бүген баш ватабыз. Халкыбыздагы тоташ кыргыйлык, имансызлык әнә шул җиңү тантаналарының бер шаукымы түгелмени? Дөрес, без миллионнарның каны, җаны бәрабәренә, кеше гомере белән һич исәпләшеп тормастан, дөньядагы афәтләрнең берсен — фашизмны җиңеп чыктык. Ләкин бу җиңүнең икенче бер афәтне — коммунизмны ныгытуына төшенә алмыйча калдык. Җиңгән ил үз гамәлләренә дөрес бәя бирмәсә, бу җиңү халыкларда шапырыну, мактану, талап баю, бүтән милләтләргә нәфрәт хисе тәрбияләсә, моның азагын хәзер әйтү кыен түгел. Илебездәге халыкларның аң дәрәҗәсенә генә карарга кирәк. Ватан сугышында җиңү, шул җиңүнең озакка сузылган эйфориясе Рәсәйнең ялкау акыллы халыкларын һәлакәткә китерде дә инде. Чит ил белгечләре, галимнәр, философлар, әдипләр, безнең ил вәкилләре белән очрашканда, гел бер сорауны биреп килделәр: «Нигә сез шулкадәрле сугыш белән мавыгасыз? Сугыш беткәнгә фәлән ел бит инде?» Әйе, Ватан сугышына багышлап төшерелгән кинолардагы сугыш эпизодларында шартлаткыч матдәләр сугышның үзеннән дә күбрәк, артыграк кулланылган икән инде! Нигә алай? Без, сугыш хәлләренә кайта-кайта, ил халыкларының күзен чынлыктан, чынбарлыктан каплап тоттык. Бүген бер юнәлештә дә алга китә алмаган, икътисады һәлакәткә килеп терәлгән

ил бары тик сугыш мактанчыклыгы, шапырынулы буш коткы белән генә яши ала иде. Әгәр инде үзгәрешләр башланып, хакимият башына Горбачёв килмәсә, Рәсәй генераллары, канга манчылган маршаллары өченче бөтендөнья сугышын башлаган булалар иде. Бүгенге ил атом сугышы хәрабәләре арасында пыскып ятачак иде. Рәсәй тарих буена бары тик сугышта җиңү рухы белән генә яшәде. Рус милләтенең дөнья фәненә керткән акыллы өлеше күпме? Ничаклы? Илнең бөтен сәрмаясы, нигездә, сугыш эшен яхшыртуга гына тотыла килде.

Конисская әсәре рус солдатының кемлеген рәхимсез рәвештә фаш итә. Җиңүчеләрне алдан торып кына түгел, арттан да карый, бәяли автор. Безнең илдәге хакимият әнә шул җиңүче-мокытлар кулына калганнан бирле, илебездә рәт, низам, тәртип, хокук бетте. Ватан сугышы ике-өч буынга һаваланып яшәргә ярдәм итте, блиндажларда кача-поса партбилет өләшеп, посып яткан полковник Брежневларга күккә сикерергә, алтын таҗлар кияргә булышты. Сугыштан соңгы буын вәкилләре арасында үткәндәге җиңүләргә ышыкланып, сугышка аркаланып, кемнәр генә рәхәт яшәмәде дә, кемнәр дөнья байлыгын чумырып калмады?! Гомумән, берчакта да сугышмый тормаган рус халкындагы ваемсызлык, гамьсезлек, ялкаулык, эш сөймәү сыйфатлары – әнә шул туктаусыз сузылып килгән хәрби җиңүләрнең җимеше ул. Шуңа алар Чехословакиягә бәреп керде[1], мадьярларны сындырды, якты дөнья күрмәсен өчен, Берлинны таш дивар белән урталайга бүлде[2], әфганнарны басып алды. Хәзер әнә Курил утраулары хакында тартыш бара. Рус: «Бирмибез!» – дип акыра. Нигә кирәк безгә ул утраулар? Рәсәйгә җир җитмиме? Җир өчен тартышмый Рәсәй халкы, аның болай да ярты җире тик, буш ята. Рәсәйгә «Җиңдек! Җиңәбез! Бирмибез!» дигән оран кирәк. Рәсәй халкы әнә шул буш оран белән җылынып яши. Монда «Киләчәк сугышларга кадәр!» дип тә әйтергә кирәк.

[1] 1955 елда төзелгән Варшава килешүе гаскәрләренең Чехословакиягә бәреп керүе турында сүз бара (1968).

[2] Германия Демократик Республикасының Көнбатыш Берлин чигендә торгызылган ныгытма турында сүз бара (1961–1989). Озынлыгы – 155 чакрым.

Шөкер, дөньяда Америка, Англия, Франция кебек илләр, аларның иманлы, динле, фидакяр лидерлары бар. Шөкер, дөньяда атом бомбалары яралды. Тыйса, русны бары шул гына тыячак.

Без, татарлар,– юаш, басылган халык. «Уянабыз, уянабыз, уяндык!» – дип, бер гасыр буена үз-үзебезне алдап юанабыз. Татар халкы дөнья йөзендә, үз миссиясен үтәп, соңгы сулышын алып ятмыймы? Безнең канда яңарыш геннары беткән булса? Мисаллары әзме әллә? Касыйм, Кострома татарларын хәтергә төшерик. Татарстаннан читтә яшәүче татарларның хәлен аңларга теләп, үз төбәгебезгә – Татарстанга игътибар итик. Татарның төп төбәгендә, яхшымы-яманмы җөмһүрият яшәгәндә, татарлардан ни калды? «Учак урыннары, учак урыннары». «Безгә яңарыш килмәсә? Уянмасак?» дигән сорауны куярга куркабыз. Чөнки аңа җавапның уңай булуы да ихтимал. Без, татарлар, көзгегә карарга куркабыз. Авыз кыек булгач, көзгегә үпкәлисе түгел иде дә... нишлисең. Тарихта җиңүчеләр яшәгән, җиңелгән илләр булган. Шведлар Рәсәйгә кергәннәр дә борылып кайтып киткәннәр. Французларның чигенүен рус шовинистлары бүген дә көлке итеп телгә ала, киноларда мәсхәрәли. Немецлар да үтеп караган Рәсәй чикләрен, японнар да... Ә руслар яулап алган җирләреннән берчакта да кире борылып чыкмаганнар! Максатлары һәрчак ачык булган: «Владикавказ!» дигәннәр алар. «Владивосток!» дип ыргылганнар... Без, татарлар,– җиңүчеләр табаны астында яшәгән халык. Халыкның бер өлеше ничарадан бичара руслашкан, милләтнең аңлы өлеше рустан мәрхәмәт көтүнең өметсезлеген белеп руслашкан, чукынган, иманын алыштырган, чит илләргә таралган. Без татардан чыккан мәшһүр русларны санап мактанабыз. Әгәр ул гали затлар татар булып калса... чукынмасалар, шул дәрәҗәгә ирешә алырлар идеме? Юк, әлбәттә. Бу хакта ике сүз булырга мөмкин дә түгел. Беренчедән, аларның генофондлары үзгәреш кичергән. Үзгәреш үз чиратында үсү таләп иткән. Икенчедән, табан астында ыңгырашып яткан татарлар үз араларыннан берәүнең дә котылып чыгуын, күтәрелүен теләмәгәннәр. Калкынырга үзләре үк ирек бирмәгәннәр. Без шуннан бирле вак, көнчел, бәләкәй булып калганбыз. Русларны сүгеп тел ардырганчы,

татарның үзенә хак бәя бирергә кирәк! Казанны руслар басып алган, имеш! Сафсата! Казанны русларга татар үзе яулап алып биргән!

Мондый уй-борчылулар миңа беренче тапкыр гына килми инде, элегрәк тә әйткәнем, язып куйган чакларым булгандыр, әмма Конисская юлларын укыганда, мин өр-яңадан шушы уйларга кайттым, элгәрге иманымны ныгыттым. Элек мин белгән кешеләрне Конисская чишендереп каршыма бастырды. Әйе, бу мемуарлар бәхетсез язмыш дулкыннарында бәхетле була алган, бәхетнең киң төшенчәсен алган хатын язмышы турында. «Страшно в этом сознаться, но после тридцати лет унижения, страха, страха, страха, я, попав под власть немцев, почувствовала себя вдруг свободной. Это звучит неправдоподобно. Ведь я тут была рабой!» Бөтен хикмәт тә шунда ки, бу язмаларны югары күтәргән сәбәп тә шунда, немец коллыгын татыган, Рәсәйнең һәлакәтен күреп торган хатын, хәзерге хәлен, халәтен кат-кат уйлагач, сәер мәгънәле нәтиҗәгә килә: немец коллыгы Рәсәйдәге коллыктан җиңелрәк икән! Йә, кайсыбызның башына бу фикернең килгәне бар? Һәм Конисскаяга бер шиксез ышанасың. Бүген, кичә, өченчекөн шикләнгән булыр идек әле. Бүген конституцион суд большевикларның ерткычлыгын күп санлы документлар, фактлар аша дөньяга белдергән көннәрдә... Юк, юк, Рәсәй чушпаннары, мокытларның аңы яктырды, димим... Кая ул! Лигачёв[1] ишеләр, эшлексез Ивашколар[2] һаман тырпылдый, бәргәләнә әле. Әле коммунистлар йөзенә ябылган битлекнең чынлап торып алып ташланганы юк... Һәм булыр дамы?.. Конисская авыз тутырып әйтеп биргән. Гаепләү сүзләрен элегрәк тә әйткәләгән, ишарәләгән әсәрләр булгалады, ләкин үз язмышыннан чыгып шундый шомлы

[1] Егор Кузьмич Лигачёв (1920—2021) — рус совет дәүләт һәм сәяси эшлеклесе, 1983—1990 елларда — КПСС Үзәк Комитеты секретаре, 1985—1990 елларда — Үзәк Комитетның Политбюро әгъзасы,

[2] Владимир Антонович Ивашко (1932—1994) — рус совет партия һәм дәүләт эшлеклесе, 1990—1991 елларда КПСС Үзәк Комитеты Генераль секретаренең беренче һәм бердәнбер урынбасары, М. С. Горбачёв отставкага киткәч, вакытлыча Генераль секретарь вазифаларын үти.

нәтиҗә ясаган кеше буларак, ул – беренчедер. Бу әсәр гадәти булмаган төзелеше белән дә мине үзенә тартты. Дөрес, ахырга таба Конисская яңадан большевизм оҗмахына кайтып, үзенә сыеныр почмак эзли башлагач, авторның тавышы үзгәрә, ул кирәккә-кирәкмәскә йөткерә, бугазын чистарта башлый, Рәсәй һавасыннан төенләнгән йодрыкны йотып җибәрә алмый. Кайсы почмактандыр ясалмалык, курку, тәлинкә тоту бүселеп чыга. Уйладым, әллә безнең ясалма, ялган тормышны бүтәнчә тасвир итеп тә булмыймы? Без шулкадәр бозылган, имгәтелгән, дөнья кануннарын аяк астына салып изгән мохиттә яшәдек ки, аны әдәбиятта бүтәнчә язып та, аңлатып та булмаганмы? Инде күр, нык тавыш белән бердәм рәвештә иң кирәкле җырны башлыйбыз да, күмәкләшеп, «Бөтендөнья юксыллары, берләшегез!»не күтәреп алабыз.

Рәхмәтлемен, Конисская мемуарлары күңелемә ХИС өстәде. ХИС яңара, өстәлә икән, адәм баласының гомере озая, суына башлаган күңеле дә җылына дигән сүз! ХИС чыганаклары саекты, үшәнләндем, тойгылар тупасланды. Кая барыйм?

*1992, 12 июль. Иртәнчәк-көндез-кич*
*Займище*

Григорий Канович[1] – Литвада, Вильнюста яшәүче яһүдләрнең милли әдибе. Дубултыда очрашып, кыска-кыска гына сөйләшкәләп йөреп, шунда танышкан идек. Бераз мактанчык куык, тере саесканнарны теләп очыртучы, һавалы, безнең ише провинциаль кабартмаларга каш җимереп, өстән генә караучы бу тәкәббер кешене мин нигәдер бер күрүдә үк үз иттем. Яшермим, Григорий Канович үзе дә мине читкә какмады, миңа тартылды. Ике сүзенең берендә ул борчак чәчеп җибәрә иде. «Слёзы и молитвы дураков»[2] исемле романым Англиядә басыла. Болгариядән корректурасын җибәрделәр, ФРГда чыга... фәлән илләрдә...» дигән сүзләрен көлемсерәп кабул иттем, ышанмадым. «Слёзы и молитвы

---

[1] Григорий Канович (Яков Семёнович, 1929–2003) – рус һәм Литва язучысы, Израиль Язучылар союзы премиясе лауреаты.

[2] Г. Кановичның 1983 елда язылган романы.

дураков», «И нет рабам рая»[1] исемле романнарын язучылар кибетеннән соратып алдым һәм гаҗәпләнеп калдым: мин «куык» диебрәк кабул иткән Канович яһүдиләрнең бөек һәм милли язучысы икән. Бу хакта матбугатта чыгышларым булды инде. Минем коткыга ияреп, улларым да Канович китапларын укып чыктылар, нәтиҗә куанычлы булды, алар да бу яһүди әдипне кабул иттеләр, яраттылар. Шушы җәйдә дачамда, чолан-кабинетымда мин Кановичның өченче әсәрен – «Козлёнок за два гроша»[2] романын җентекләп укып чыктым һәм чын мәгънәсендә таң калдым. (Минем бу таң калуым үтә ихлас һәм чын күңелдән озакка булыр!)

Мине ике нәрсә искиткеч сокландырды. Кановичның теле. Гади тел белән язмый ул, телен җанландыра, һәр җөмләсен диярлек чагыштырулар, сынландырулар, җанландырулар белән бизи, бизәкли. Романнар дәвамында ничаклы гүзәллеккә төрелгән җөмләләрне укып сөенәсең. Гап-гади тормыш хикмәтләре Канович теленә кергәч җанланалар, бизәкле тел чаралары аша күңелне җылытып йомшарталар. Бүген аннан мең мисал китереп булыр иде, чөнки Канович геройлары – таш кисүче Эфраим, сучы Шмуле-Сендер, хәерче Авнер Розентальләр – әсәр дәвамында зирәк пәйгамбәрләр, тапкыр философлар, тирән фикерле яһүдиләр булып, күңелдәге изге уйларны, яхшы ниятләрне ныгыталар. Югарыда саналган кешеләр – барыннан да бигрәк чәчрәп торган яһүдиләр, еврей халкының уллары. Бармы яһүд милләте, аның вәкилләренә нинди төп сыйфатлар хас, дигәндә, әсәрдән бу сорауга тулы җавап алып була. Әсәрдә телгә алынган һәркем, баймы ул, ярлымы, хәерчеме (Канович тиккә генә таш юнучыны, сучыны һәм хәер эстәп көн күрүчене сайлап алмаган!), бер-берсен чиксез нык ярата! Яһүд булганы өчен ярата! Үзе шул милләт кешесе булганы өчен, милләттәшенә тиңсез мәхәббәт саклый. Әйе, әсәрдә күпчелек Литвадагы «местечковый еврейлар» тормышы үзәккә куела. Әмма автор гасыр башындагы яһүдиләр тормышы материаллары аша персонажларның бер-берсенә ихлас хөрмәтен, мәхәббәтен, самими мөнәсәбәтен белдереп кенә калмый, еврейлар язмы-

[1] Г. Кановичның 1985 елда язылган романы.
[2] Г. Кановичның 1987 елда язылган романы.

шына да бөек мәхәббәтен белдерә. Бу өч роман дәвамында мине иң нык таң калдырганы шул булды: Канович, автор, үзе дә яһүд милләтен, аның гореф-гадәтләрен, иманын, динен, дин әһелләрен, һәр җан иясен какшамас, бетмәс мәхәббәт белән ярата. Еврейларның язмышы аны борчый, шуңа күрә авторның һәр сүзеннән, ишарә-ымыннан ут бөркелеп тора. Ул яһүдиләрнең тарихына, милләтнең иманын тудырган бөек шәхесләргә, җай чыккан саен, мәдхия укый. «Яратам!» дип кычкырмый, шапырынмый, әмма еврейларның билгеле бер чорда, мәгълүм шартларда аларның бер-берсенә ничаклы ярдәмчел икәнлегенә сөенә-сөенә яза. Горурлана автор үз милләте вәкилләре белән! Акыллы, хәйләкәр, эшчән, тырыш халык яһүдиләр. Ремаркның «Возлюби ближнего своего»[1], «Ночь в Лиссабоне»[2] романнарында михнәт чигеп йөрүче яһүдиләрнең бер-берсенә тоташкан җылы кулларын укып, күзләремә яшь килгән чаклар бар иде...

Әдәбият, асыл әдәбият, тарихка багана булып басарлык әдәбият бары тик милли генә була ала. Ходай коллары – адәм балаларын бары тик милли мәйданда гына тулысынча аңлап вә аңлатып була. Толстой[8], Достоевскийлар[9]... Канович – милли язучы. Ул үз өстенә милләтен дөнья мәйданында күрсәтү бурычы алган. Һәм искиткеч зур уңышка ирешкән. Ә бездә? Татарларда? Үз милләтен яраткан әдипләр бармы? Гомумән, татар прозасы вәкилләре татар дигән халык вәкилләрен кайсы чорда, нинди итеп тарихта беркетеп куйганнар? Әдәбиятта беркетеп куелган тарихны төптән бозу мөмкин түгел инде. Алдагы көннәрдә яңа шәхесләр Толстойны, Достоевскийны ничаклы бозарга тырышсалар да, алар беркетеп киткән рус – рус булып калачак инде. Рус халкының вәкилләре булып Карамазовлар[3], Мармеладовлар[4], Смердя-

[1] Эрих Мария Ремаркның 1941 елда язылган романы.

[2] Эрих Мария Ремаркның 1962 елда язылган романы.

[3] Ф. Достоевскийның «Братья Карамазовы» романы (1879–1880) төп геройлары.

[4] Семён Захарович Мармеладов – Ф. Достоевскийның «Преступление и наказание» романы (1865–1866) герое.

ковлар[1], Мышкиннар[2], Карениннар[3], Вронскийлар[4] тезелеп торачак. Безнең татарда татарны яраткан әдипләр бармы? Татарда нинди милли сыйфатларны әсәрләрендә тапканнар алар? Татар язмышын нинди мисаллар белән ачарга тырышканнар? Мин быел җәй үткәндәге прозачыларның иҗатына кайтып карый башладым. Тар, кара милләтчелекне кан дошманы итеп санаган бөек психолог Фатих Әмирхан. Татарны чиксез сөйгән, үз татарын Европа кешесе итеп күрергә ашкынган остаз. Сәмигулла абзыйлардан[5], Фәтхулла хәзрәтләрдән[6] көлеп, аларны чеметеп-чеметеп алса да, Фатих Әмирхан татарны бөтен барлыгы белән яраткан... Мәҗит Гафури[7] белгән татар дөньясы бөтенләй башка. «Тормыш баскычлары»ндагы[8] шәкерт-күсәкләр... «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек»тәге[9] бичара, мескен, уйсыз, надан, көчсез татарлар. Күр инде ул «Ярлылар, яки Өйдәш хатын»ны![10] Берберсенә ярдәм кулы сузарга әзер татарлар да нинди мескен, зәгыйфь... Гомумән, Уфага килгән Тукайны өенә чакырып чәй дә эчерә алмаган «Габделмәҗит мин бичара» татарда бары тик мескенлек, аңгыралык, көчсезлек кенә күргән. Үзенчә Гафури да татарны яраткандыр, мәгәр аның язмалары татарга рух өстәмәгән, әдип, һәрдаим татарның баш түбәсенә

[1] Павел Фёдорович Смердяков – Ф. Достоевскийның «Братья Карамазовы» романының (1879–1880) төп геройларыннан берсе.

[2] Князь Лев Николаевич Мышкин – Ф. Достоевскийның «Идиот» романының (1867–1868) төп герое.

[3] Алексей Александрович Каренин – Л. Толстойның «Анна Каренина» романының (1875–1877) төп герое.

[4] Алексей Кириллович Вронский – Л. Толстойның «Анна Каренина» романының (1879–1880) төп герое.

[5] Ф. Әмирханның 1916 елда язылган «Сәмигулла абзый» хикәясе герое.

[6] Ф. Әмирханның 1909–1910 елда язылган «Фәтхулла хәзрәт» повесте герое.

[7] Габделмәҗит Нургани улы Гафуров (1880–1934) – татар һәм башкорт язучысы, фольклорист. БАССРның халык язучысы (1923).

[8] М. Гафуриның автобиографик характердагы күләмле әсәре (1927).

[9] М. Гафури хикәяләре җыентыгы (1904).

[10] М. Гафури хикәясе (1905).

зәгыйфь йодрыгы белән төеп, көчсез иреннәре белән аны җәһәннәмгә этәргән. «Татарлар... сез бетәсез...» Галимҗан Ибраһимов социалистлар, большевиклар арасында татар революционерларын эзләгән. Татар тормышын каһәрләгән, татарның бары тик кара якларын гына күргән. Революцион идеяләр татарны яктылыкка илтә дип, балаларча ышанган. «Татар хатыны ниләр күрми»25 әсәрен генә кара. Булгандыр, яшәгәндер андый татарлар да. Ләкин тарих алдында татар хатын-кызларының язмышын шулкадәр чикләнгән, кара, каһәрләнгән итеп күрсәтү белән Г. Ибраһимов та татарны артка сөйрәгән. Шәриф Камалның беренче бөек хикәяләре. Илләреннән язмыш сөргән «Акчарлаклар»[1]... «Уяну»дагы[2] Муса да рус шәһәрендә иза чигә бит... Читтә, эт кулында... Социалистик реализм кысасына ирекле баштан кергәнче, Шәриф Камал гүзәл бер язучыбыз булган, татар өчен янып көйгән... Менә безнең дөньяга Гаяз Исхакыйны кайтарырга тырышабыз. Исхакыйның татарга мөнәсәбәте бөтенләй бүтән! «Тормышмы бу?»[3] дигән шактый төшенке әсәрендә дә татарлар чын кешеләр рәвешендә тасвирлана. «Ничто человеческое им не чуждо!»

Югарыда саналганнар, егерменче гасыр дәвамында татар милләтенең, татар халкының яшәү рәвешен, иманын, характерын, гүзәл вә кара якларын үз әсәрләре аша тарихка беркетеп калдырган шәхесләрнең татарга мөнәсәбәтләре төрле-төрле булган. Бусы – бәхәссез. Шул мисаллардан чыгып, әдипләрнең үзләренең кемлеген дә, татар халкының яшәү рәвешен дә ачарга тырышып, бер нәрсә язарга кыҗрап йөрим. Вакыт җиткерә алсам, Ходай гомерне җәлләмәсә, шәт, иншалла, язып та куярмын әле.

Соңгы елларда мин Ә. Еники, М. Мәһдиевләр иҗатын күтәреп, шәхес буларак аларны гел мактап киләм. Мин аларның иҗатын шулай бөек дип санаганга түгел ул. Әмирхан абыйның да, Мәһдиевнең дә уртакул әсәрләре бар, алар да – безнең барыбыз кебек үк куркак, сак язучылар. Алар инде «милләт» дип тә язгы ташкынга күкрәкләре белән атыла тор-

[1] Ш. Камалның 1914 елда язылган повесте.

[2] Ш. Камалның 1914 елда язылган хикәясе.

[3] Г. Исхакый романы (1911).

ган җаннар түгел. Тәмле ашап, рәхәт кичереп, кәеф-сафада яшәгән, шулай яшәү рәвешен генә кабул иткән барчуклар. (Үзем дә алардан калышмыйм!) Ләкин бер нәрсә бар: Әмирхан абый Еники дә, Мөхәммәт Мәһдиев тә – татарның милли әдипләре, алар татарны ярата алалар, аның җанын аңлыйлар. Менә нәрсә кыйммәт минем өчен! Шул сыйфатлары белән алар үз чордашларыннан нык аерылып торалар. Әгәр Еникиев белән Мәһдиевтә чорның социаль каршылыкларын аңлау, шул каршылыклар чарпылышында үз төп урыннарын билгеләү көче дә булса, алар татар тормышын дөнья мәйданына чыгарырлык әсәрләр яза алыр иде. Һичшиксез. Без, татарлар, дөнья биеклегендә уйлау сәләтеннән мәхрүм ителгән, ә әдип, милләтен ташлап узып, берчакта да ерак китә алмый! Татарлык-тарлык һәммәбезнең итәгеннән тота!..

Канович – философ. «Дети – это не близкие. Дети – это далёкие» дип кистереп куя. Мең хаклы яһүд! Мин, «Дети – близкие!» дип алданып, юанып, киләчәгемне якты итеп күрергә тырышкан мәлдә... «Враньё – вино бедных, медовый напиток горемык» ди ул. Мин Эрих Мария Ремаркка табынган кебек үк, Канович та аны үз итә шикелле. Урыны-урыны белән әсәр дәвамында Ремарк аһәңнәре яңгырап, әсәрне тагын да биеккәрәк менгерә. «Так пусть же бесконечно длится это ночь! Старик Эфраим загоняет в неё своих детей, как загоняет в хлев». Вакыт турында аның үз фәлсәфи фикере. Сокландыргыч дәрәҗәдә туры, усал хөкем чыгара Канович Вакыт төшенчәсенә. «Время! Что такое время?» думает Эфраим. Паучая сеть, раскинутая над нами. Меняются пауки, мухи, а сеть висит и висит. Как только из нас высасывают кровь, в неё попадают другие, и так изо дня в день, из века в век, и нет метлы, чтобы вымести из нашего дома, из нашего сердца». Ремарк аһәңнәре, Хемингуэй тавышлары. Канович аша да мин үземнең бөек пәйгамбәрләрем белән очрашам.

«Козлёнок за два гроша» шушы трилогиянең соңгы китабы булса кирәк. Алдагы ике китапта очраган шәхесләр аратирә монда да чагылып, вакыйгаларга катнашып китәләр. Һәр өч китапның яһүдиләр язмышына караган нигезле чыгармалары бар. Гыйбрәт! Яһүдне изәләр, кысалар, ул һәр тарихи чордан тагын да дус, тату, көчле, искиткеч ярдәмчел һәм

хәйләкәр булып яшәвен дәвам итә. Нигә без андый түгел?! Без һаман кысыла, тарая, кечерәя барабыз. Һәм «татар инде тарихта үз язмышын хәл иткән» дип раслауга кем каршы чыга ала?!

Эфраимның үз балаларына булган тиңсез мәхәббәте мине тетрәтте. Этэль Лилиан Войничның[1] «Кигәвен»[2] романында Монтанелла атаның Артурга ташкын мәхәббәте (әгәр ул чын булса!) чиксез кайнар, бөек һәм мәңгелек була. Эфраимның балаларга белдергән эчке уйлары — дәреслекләргә керерлек бөек юллар...

Канович белән без хатлар да алыштык. Мин аңа да китабымны җибәрдем... Ни аяныч, минем уртакул әсәрләр, уртакул тәрҗемәчеләр аша үтеп чыгып, аның күңелендә теләктәшлек уятмадылар шикелле. Дөрес, Литвада хәлләр үзгәрде, азатлык көрәше башланды. Канович СССР Югары Советы депутаты итеп сайланды. Азатлык хәрәкәтендә яһүдләрнең ниндидер җәмгыятен оештырып җибәргәч, аның сәяси хәле авырайган икән, дигән хәбәрләр килеп иреште. Хат язарга кыҗрап йөрим. Израильгә китте, дигән хәбәрләр дә йөрде...

[...]

*1992, 5 сентябрь. Көндез*
*Казан*

Машинка сердәшем янына күптәннән якынайган юк икән, көннәр аҗаган шикелле кабыналар да эзсез-нисез офык чоңгылларына сеңәләр. Август азагы — сентябрь башларының истә калырлык вакыйгалары да артык зурдан түгел: гадәти тормыш, гадәти ыгы-зыгылар, колакка эленгән зармоңнар. Иң мөһиме — төнге дәһшәтле уянудан соң, хәмерне авызга алганым юк. Ял итәм. Бу — хәзерге дәвердә минем өчен бик мөһим. Бер ягы бар: аракы — замандашларым белән бәйләп торучы бердәнбер чара, дисәм дә хата булмас... Бу хакта — соңрак.

---

[1] Этэль Лилиан Войнич (1864–1960) – Ирландия һәм Англия язучысы, композитор.

[2] Э. Войничның 1897 елда басылып чыккан романы.

Беренче нәбәрәмне – Искәндәр кызы Галияне – мәктәпкә илттек, 68 нче мәктәпнең татар классына. Мәктәптә беренче тапкыр татар классы туплаганнар, директорлары – татар хатыны. Кереш сүзендә, ичмасам, ник бер сүз татар файдасына чыксын! Татарстан хакында, яңа оешырга торган татар сыйныфы турында авыз ачып ник сыңар сүз әйтсен! Әле классларда – «командирлар», алар җәйге ялда мәктәпне төзекләндерүдә катнашкан активистларга Мактау кәгазьләрен тапшырырга тиешләр. Казарма, шул ук соцсистема... Берзаман бакчада, яшь каеннар арасында, нәни кызым Миләүшә, Искәндәр, мин фотога төшәргә җайлы урын эзләп йөри идек, сукмактан җылый-җылый Галия йөгерә... Өенә тыр-тыр чаба... Классташларын югалткан да чаба! Каян ишек тапкан диген!.. Без очрамасак, кайтып та китәсе... Рәхәтләнеп көлдек. И бала, сукмагың адашудан башланды, абай бул, соңгысы булсын!..

Тавлин[1] «Ватаным Татарстан»га чираттагы гайбәтен, яласын, йогышсыз гаепләүләрен илткәннән бирле, мин аны, Гурийның фикердәшләре Мансур Вәлиевне, Җәвад Тәрҗемановны, «Шәһри Казан» газетасын судка бирергә уйладым. Литвин белән киңәштек, ялгышмас өчен, уңны-сулны исәпләштек. «Бир, ерт шуларның кара битлекләрен!» – ди Фәрваз[2]. Литвин: «Син отасың. Вакыт җитте! Судка бир!» – ди... Уйладым-уйладым да прокурор танышым Фәнил Галиевкә шалтыраттым. Союзда очраштык, кыска гына итеп, эшне, аның тарихын һәм Гурийның миңа яккан гайбәтен сөйләп бирдем. «Син хаклы,– диде Галиев.– Судка бирердән элек, җөмһүрият прокуратурасы карамагындагы реабилитация комиссиясенә мөрәҗәгать ит. Алар, җөмһүрият прокуроры Сәйфихан Хәбибуллович Нәфиев боерыгы белән, Мәҗит Рәфыйковның[3], Адлер Тимергалинның төрмә-тикшерү эшләрен соратып алырлар һәм һәркайсының гаеп дәрәҗәсен законча билгеләрләр. Шушы белешмәгә таянып, син халык

[1] Гурий Иванович Тавлин (1925–1998) – язучы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1996).

[2] Фәрваз Мөхәммәдулла улы Миңнуллин (1934–1994).

[3] Мәҗит Мәгъсүм улы Рәфыйков (1925–1986) – язучы, тәрҗемәче.

судына барырсың», – диде... «Эшләр белән якыннан таныш Рафаэль Мостафинга әйтеп кара: һәммәсен өйрәнгән, фикер йомгагы бар, язып чыксын көндәлек матбугатта бер-бер мәкалә!»

Рафаэльгә шалтыраттым, дүшәмбедә очрашырга вәгъдәләштек...

Прокурорга барырга дигәндә... Комиссия әгъзаларына дәшеп карарга кирәклеген белгәндә... Кан суынып китте. Прокурорлар янына барасым килми. Һич! Чит элементлар алар! Чал башыңны иеп, гаепле кеше кыяфәтендә алар катына бар инде... Литвин шалтырата: «Судка үтенечеңне яздыңмы?» – ди. Яһүд эш сузылганны, эленке-салынкы йөргәнне яратмый шул: Литвин, тешли икән, өзмичә туктамый. Аның бу сыйфаты мине куркыта да, сокланам да. Талпан булып ябыша инде: ычкындырмый, ычкынмый да. Без татарлар – үзгә хайваннар шул, без тешләү түгел, якынаерга да шүрлибез... Мин бигрәк тә. «Пуганая ворона куста боится!»

Әгәр Тавлинны тыяр көч табылса, әгәр аны судсыз да авызлыклап булса, ни пычагыма миңа суд бусагаларын таптап йөрү?! Кемнәргәдер эч сереңне ачу, аларны – бүгенгенең ваемсыз тук кешеләрен – моннан кырык ел элек булган ямьсезлекләргә сөйрәп алып кайту? Аңларлармы алар, кабул итәрләрме? Мәзәк хәлгә калмаммы? Аннары... мәет белән, үлгән Мәҗит белән авыз чайкап, аның мәкерле язмышын, юк, пычраклыгын ачу килешерме? Әгәр Тавлин китергән соңгы мәкалә дөнья күрсә, эш бүтәнчә булыр иде! Ул инде минем исемне авызын тутырып әйтә, пычрата, күмә, таптарга омтыла. Омтылмас иде, җитмеш елга якын эшләгән бердәнбер сыңар эше – «Афәт»[1] романы юкка чыга! Шулай булыр анысы, кемдер дөреслекне ачарга җай табар. Хәзер чүп-чар кешеләргә, көнчеләргә, вак-төяккә юл ачылды. Әнә ич «Татарстан яшьләре» редакторы әйтеп торды: «Әсрар Галиев[2] сезнең өстән бик ямьсез мәкалә җибәргән, бас-

[1] 1996, 2007 елларда чыккан Г. Тавлин романы.
[2] Әсрар Әбрар улы Галиев (1938–1998) – язучы.

мадык»,– диде. Илдус Илдарханов[1], Шамил Рәкыйповлар[2] хәзер көтеп кенә торалар инде. Каян да булса бер кара шәүлә килеп чыкса, «тотыгыз, тот, Аяз бу!» дип, дәррәү акырачаклар. Вак җаннар, языкка баткан мәхлуклар эшләгән кешене, уңышка ирешкән затларны гомерләре буена сагалыйлар, алар үч укларын әзер тоталар, кыек атып туры тидерсәләр, алардан да бәхетле кеше юк. Көнчелек, күремсезлек, ваклык, гайбәт дингезендә яла җилкәннәрен киереп йөзү – татарның төп милли сыйфаты. Татар зыялыларында бу сыйфат аерата калку чагыла.

Тавлинның агулы уклары баш очымда хәзер туктаусыз оча... Дуэль заманнарында рәхәт булган, мәсьәләне ирләрчә хәл иткәннәр. Бүген мин, наган тотып, шул кара йөз белән атышырга чыкмас идемме?.. Кем-кемне! Иң туры, гадел чишү юлы әнә шул. Ходай Тәгалә мине якламас идеме? Бар, гөнаһларым бар, әмма соңгы утыз-кырык ел эчендә мин беркемгә берниндн явызлык эшләмәдем, беркем исеменә шикаять язмадым, гайбәт таратмадым. Яшьлектә кылган хаталар өчен мең мәртәбә тәүбә кылдым, гөнаһларымны яхшылыгым белән юдым. Көчсезләргә ярдәм кулы суздым, төрмәдә утырганнарга, әсирлектә булганнарга беренче булып ярдәмгә ташландым. Бу хакта аерым язып куясы да бар әле...

* * *

Тавлин романы басылып чыккач, аны хуплаучылар ешайды. Ниһаять, үзен прозаның төп белгече итеп санаучы Фоат Галимуллин[3] да үз сүзен әйтте... Бөтен кешенең шикле күзе миңа килеп тукталгач, мин моңарчы сер, ризык, хатирәләр һәм язмышымны бүлешкән иптәшләремә ап-ачык, аек күз

---

[1] Илдус Гәрәй улы Илдарханов (1944) – журналист. Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (1988), Татарстан журналистларының «Бәллүр каләм-2004», «Бәллүр каләм-2010» бүләкләре иясе.

[2] Шамил Җиһанша улы Рәкыйпов (1929–2005) – язучы. РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1979).

[3] Фоат Галимулла улы Галимуллин (1941) – әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, профессор, тәнкыйтьче. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1996), Татарстан Язучылар берлегенең Җ. Вәлиди исемендәге әдәби премиясе лауреаты (2005).

белән карый башладым. Бүтәнчә алданмыйча, дөреслек бөртекләрен ялган кибәгеннән аерып алып карыйм да... ни күрәм: озак заманнар аралашкан, минем эч серемнең бөтен җиде катламын белгәннәр дә тиз-тиз карашларын үзгәрттеләр. Шәүкәт[1] посты. «Мин газеталарны да, журналларны да укымыйм»,– диде. Илдарларның[2] – үз мазасы. [...] Илдарның күз карашы шушы игелексез улы Илгиз белән чикләнгән. Күңелендә үзгә уйларга урын юк. Хәзер шифаханәдә ята, диләр.

Күпләр, очрашканда, күзләрен түбән төшерә, янәсе, уйларын яшерә...

Күпләр ялган теләктәшлек күрсәтә, юри кычкырып, тантана белән сөйли башлый. Берәүнең дә ачыктан-ачык әйткәне юк дип әйтә алмыйм, Шәриф Хөсәенов[3] (ул гомергомергә туры сүзле һәм кискен хөкемле булды!) болай диде: «Синең яшь чагында КГБга хезмәт итүләрең турындагы романны көч-хәл белән укыдым. Конарсыз, тозсыз, чилепешле роман. Ә сине гаепләмим, ул чакта кемнең кем булуы аның үзеннән тормаган... Хәзерге заман югарылыгыннан торып хөкем итү җиңел ул!» Дәшмәдем, бу сүзләрне ишетмәгәндәй булдым. Акланасым да, моннан кырык ел элек кылган гамәлләре өчен Аязны сүгәсем дә килми. Моны бүгеннән торып аңлату читен булмас, ләкин мин көткәнчә, мин теләгәнчә аңлаучы булырмы? Бусы шикле.

Янымда кем калды? Кемнәрнең янәшәмдә булуын теләгән идем?

Гариф[4] һични сиздермәде. Аның үзенең дә хәле мөшкел. Аны да туктаусыз тәпәлиләр, дөмбәслиләр. Ничарадан бичара без бер-беребезгә тартылабыз. Гарифны түгел, системаны, система тудырган мөнәсәбәтләрне, система сеңдергән кануннарны гаепләргә кирәк тә бит. Татар акылы кыска, ул үз янында торган кешене изеп тә үч тойгысын куандыра, еракка карый алмый, үрелер иде – кулы гына түгел, акылы да богаулы. Очрашканда, ул хакта кычкырып әйтмәсәк тә, без бер-

[1] Шәүкәт Гали улы Һидиятуллин (1928–2011).

[2] Илдар Гафур улы Юзеев (1933–2004).

[3] Шәриф Нургали улы Хөсәенов (1929–1999).

[4] Гарифҗан Ахунҗан улы Ахунов (1925–2000).

беребезне иплəп кенə юатабыз. Əлбəттə, күп очракта уртада шаһит булып шешə-хəзрəт утыра! Гарəф[1] соңгы вакытларда нык сала. [...] Кирəкме икəн?

...Ринат Мөхəммəдиев мине яклаган булып кылана. [...] Үз җае өчен гел турыдан бара, кем очраса да таптый. [...] Хəзер аңа йөзлəр теш кайрый, лəкин татар бу очракта да үзе булып кала: йодрык кесəдə, сүзлəр теш читəне артында посып ята, җылан кебек бəргəлəнеп...

Туфан Миңнуллин – бухгалтер, ул адымнарын да, кемнең баскыч араталарының кайсы биеклектə торуын да дөп-дөрес исəпли. Югарыга – өстəге басмаларга үрелеп караганда, аскы аратага нык ятып, аскы аратага нык итеп аякларын куйган. Арата бу очракта – мин ул...

Ризван[2] янəшəмдə калды. Рөстəм Мингалим, тагын кем?..

Ничə еллардан бирле Мөхəммəт Мəһдине йөрəгемə якын кабул итеп, кулымнан килгəнчə, аны аңлатып, аңлап, дəртен үстереп килəм.

Мөхəммəт – чуар кеше. [...] Гомəр Бəшировның кияве генə түгел, тугры шəкерте дə. [...] Хəтерлим: берзаман М. Рəфыйковның миңа суктырган шигырь юллары «Татарстан яшьлəре» газетасында басылды. Мансур Вəлиев кереш сүзе белəн, əлбəттə!.. Ничектер шул көнне Мөхəммəт белəн телефоннан сөйлəштек. «Бүген миңа унбишлəп яшь шагыйрь: «Укыдыгызмы, Аяз турында Рəфыйковның поэмасы басылган»,– дип шылтыратты»,– диде Мөхəммəт. Сөенече тавышына чыккан иде. Гомумəн, күпме яшəп, янəшə иҗат итеп, Мəһдиевнең минем əсəрлəргə бəя биргəне бармы?! Юк ич! Авызында – су! Авызында – су суын, күңелендə ни?

Татарлык тарлыгымы, көнчелекме? Мин бу хакта уйламаска тырышып яшəдем, аның мокыт тынлыгына исем китмəде, бу – чын, хак уем. Мин берчакта да Мөхəммəттəн көнлəшмəдем, аны татар дөньясы өчен иң кирəкле шəхеслəрнең берсе итеп санадым. Мөхəммəтнең татар дөньясына кылган якты хезмəтлəре бихисап... Ə кеше буларак... Чуар кеше ул. Бу сүзне кем ничек тели, шулай аңласын. Чуар! Соңгы мисал. Мин идарəдəн, М. Рəфыйков эше белəн

[1] Гарəфетдин Низаметдин улы Шəрəфетдинов (1929–2011).

[2] Ризван Мирхəбибулла улы Хəмидуллин (1941–2017).

танышу өчен, Р. Мостафин һәм Мөхәммәтне җибәрүләрен сорадым. Мөхәммәттән алдан ук белештем: «Барасыңмы?» – дидем. «Барам!» – диде, вәгъдә бирде. Гаепсез икәнлегемне нәкъ менә Мөхәммәт Мәһди күрүен теләдем. (Онытмадым «унбиш яшь шагыйрьне». Һич онытмадым!) Рафаэль барды, Мөхәммәт тыелып калды... Шул көннәрдә кулы сынган иде, шуны сәбәп итте. Хәзер уйлап куям: сынмаган аның кулы, КГБга бармас өчен генә, юри гипслап асып йөргән! Барырга, халык алдында фикер әйтергә курыккан! Монда Бәширов Гомәр кулы уйнамаганмы? «Йөрмә, буталма, катнашма!» – дигәндер.

Сак кешене шикле киңәш һәрчак тыя, яманлык эшләүдән дә, яхшылык кылудан да тыя. Әгәр бүген Мөхәммәт Мәһдиев Рәфыйковның кемлеген, аяк терәп, халык алдында ачып салса... Тавлин койрыгын бот арасына кыстыра иде. Мөхәммәт миңа олы мәшәкать тудырды. Тавлинның тавышы көрәйде, «Ватаным Татарстан»га тапшырган соңгы яласында ул: «Заявление Р. Мустафина на правление на его совести»,– дип түшен киерә, бугаз төерен уйната. Бу очракта да Мәһдиевкә ачуланмадым, бу язмаларым – үзем белән үзем сөйләшү генә. Инде Мөхәммәткә дә кинә саклый башласам... бу дөньяда кемгә карап юаныймын? Юлда, сәфәрләрдә, Мөхәммәт – искиткеч иптәш: белмәгәне юк, тарихны, татар тормышын мең мисаллар белән җанлы итеп сурәтли ала, һич иренми, арымый, талмый, нәзберек түгел, ярдәмчел, игътибарлы, кечелекле. Дөрес, саран. Юлга бирелгән күчтәнәчләрнең зурысын эләктерергә тырыша, юл букчасына аракы тыксалар, ул шунда сеңә... Мондый ваклыкларга карап, минем фикерем үзгәрми, табигатем комсыз түгел, бар булганы миңа җитә. Бүген иртәнге чәйдә меню: чөгә балыгыннан уха. Балык. Кипкән миндаль. Хөрмә. Авыл сөте. Каймак диярлек куе. Искиткеч тәмле алма. Ак май. Сыр. Венада эшләнгән «Мокка-гранде» кофесы. Кара икмәк. Бер бөтене биш тәңкә. Иртәнге ашым начар түгел ич! Без гомергә ашка-суга мул яшәдек, акча җәлләмәдәк. Әле дә туктаусыз балыкчыларга барып йөрибез. Чөгә тота торган чак җитте. Кыйбат та сатмыйлар. Килосы алтмыш тәңкә. Бүгенге бәяләрдән исәплә-

гәндә буш диярлек... Әллә мактанасым килеп китте инде? Моңарчы мактанганым юк иде бугай...

Атнакичтә көне буе Займищеда булдым. Быелгы елның гаҗәеп җылы, йомшак, иркә көннәре булып үтте. Нәкыя белән кундык та, мин көндез кайтмадым. Алмагачлар җимешләрен тотып тора алмый, ботаклар сыгылды, сынды... Ә алар көннән-көн авыраялар, балланалар. Алмагачлар дөп тә дөп җир шарын кыйныйлар. Мин кычкырып диярлек аларга дәшәм: «Югославиядә сугыш... Абхазиядә кырылыш... Карабахта бетеш... Таҗикстанда наданнар күтәрелеше. Кан коеп аңлашырга маташалар. Тагын Җир шарының кай почмакларында җан коела да, кан коела?! Бер-бер тын почмак бармы? Ник кыйныйсыз, алмагачлар, үзегез тамыр белән ябышып торган Җир-ананы?!» Кыйныйлар шул! Дөп тә дөп!..

* * *

Моннан уналты ел элек «Яшь ленинчы» газетасында «Күзгә-күз» повестем басылган иде. «Социалистик Татарстан»ның 1976 елгы 15 февраль санында Җәвад Тәрҗеманов күсәк күтәреп чыккан икән. «Совет әдәбияты» журналының 6 нчы санында (1976) шул мәкаләгә мөнәсәбәт белдерелгән, проза һәм балалар әдәбияты секцияләре утырышында каләмдәшләр мине яклап чыкканнар икән. Шул заманнан бирле Җ. Тәрҗемановның миңа бәйләнми калганы юк икән[1]! Күптән түгел генә «Карусель-әшнәя» дигән шигъри фельетонында миңа кадалды. «Шәһри Казан» газетасында басылган «Комсызлар хакимияте» дигән мәкаләсе, асылда, мине үтерү, бетерү теләге белән язылган... И көчекләр! Крылов[2] бабай «моськалары»! Әйдә, өреп рәхәтләнегез! Журналдан махсус эзләмәдем, иске саннарын актарганда, күземә чалынды. Бәлки, ул «урман бете»нә, «яр бакасы»на элегрәк җавап бирергә кирәк булгандыр? Бер авызын томаласаң, капка астыннан җәһәннәмгә кереп кача торган явыз эт ич ул!

[...]

[1] Кара: Тәрҗеманов Җ. Күзгә-күз карап. Реплика // Социалистик Татарстан. – 1976.– 15 февраль.

[2] Иван Андреевич Крылов (1769–1844) – рус язучысы.

*1992, 15 октябрь. Иртән*
*Переделкино*

Былтыр ай башында килеп, 26 ноябрьдә 114 нче бүлмә белән саубуллашканмын икән. Ризван Хәмид белән бергә булдык, җитәкләшеп кайтып та киттек. Кайтсам... Гурий Тавлинның романы басылып чыгып, Казан гөж килгән икән. Бичара Нәкыя, үз иренең Мәҗит Рәфыйковны «сатканын» белеп, рәнҗеп, каргап, журналга бер хат та юллаган, имеш. Татар язучыларының үземә булган мөнәсәбәтләрен шушы көннән башлап тулылыгы, авырлыгы, аяусызлыгы белән татый башладым. Уңнан да, сулдан да тешләргә тотындылар. Чәйниләр, Язучылар союзына аноним хатлар китереп ыргыталар. «Стукачу» дип, хат букчасының тышын ук бизәп салалар. Чамалыйм кемнәр икәнен, күңелдән беләм, әмма берәүнең дә чыраен ертып, якасыннан каерып ала алмыйм – аларның кулында Гурийның романы... Укый алмадым, күз йөгертеп чыктым, шул арада да гайбәтнең, Гурийның кара яласының агуы күзәнәкләремә сеңеп калды. Татарча газеталарны явызлык көтеп, каным катып, көчем суынып ала идем. «Тагын кем, кайсы почмактан күсәк белән башыма орыр икән?», «Чиратта кем?!» Иң гаҗәбе: Гурийга отпор бирүнең юлын табалмыйм. Чөнки мин Мәҗитнең «эш»ен күргән-белгән кеше түгел, үз эшемне дә, кемнәрнең нинди җаваплар, нинди күрсәтмәләр беркетүен дә белмим... Рәхмәт, Алексей Львович Литвинга рәхмәт! Ул Мәҗит Рәфыйковның «эш»ен табып алган, танышкан, укыган... «Син түгел, ул сине саткан. 1944 елдан КГБ агенты Рәфыйков, Уфада укыганда, студентларны сатып эзен күрсәткән дә, аны Казанга күчергәннәр. «Эш»тә агент булуы да, Михеев кушуы белән 100 сум акча алып, сине аракы белән сыйлап, провокацион әңгәмәләр алып баруы да ап-ачык ярылып ята. Син аны «илнең патриоты!» дип яклап барасың, ә ул, КГБның түләүле агенты, пычрак белән күмә»,– диде Литвин. Үземнең Мәҗиткә карата ак булуымны белә идем, хәзер дә ышаныч артты... әмма моны халыкка ничек, нинди юл белән җиткерергә? Әгәр Мәҗит исән булса, якасыннан урап алып болгап ыргытыр идең дә... шалишь! Хыянәтче хаин балчык астында миннән көлеп ята, кара этнең шакшысы ак эткә йогып калган, дош-

маннарым аның исемен калкан-байрак итеп, көн туды исә, мине изәләр.

Һай бу бер ел! Ятсам-торсам, исемдә шул гына булды. Төннәрен уянып, йөрәгем аша Фәүзия Бәйрәмованы, монафикъ көнче Гурий Тавлинны, әдәби күле кибеп аңгырайган Мансур Вәлиевне, астыртын-шома Тәүфикъ Әйдине үткәреп газаплануларымны бер үзем генә беләм!

Хак, мең тапкыр хак: үч аласы килгән, явызланган мизгелләрем дә булды... Тик үчне кемнән аласың? Төп гаеп Мәҗиттә бит! Үлгәннәр белән көрәшү – егетлек түгел, ятам-ятам да, таңнарда кан төкереп онытылырга тырышам. Чак-чак тынычланам, үзем сайлаган эш сукмагына төшәм дигәндә генә... тагын бер шәүлә ярала да, күкрәк уртасына төбәп, агулы угын ата. Тавлинны, Мәҗитне уйламаган бер минутым булды микән? Кулдан һәммә эш төште, зиһен дивардан чәчрәп төшкән дәү көзге сыман челпәрәмә килде, яхшылык белән яманлыкның чикләрен тоймый башладым. Тәмле-тәмсез, әче-төче бер булып китте, авызның тәме югалды. Исләрне аермыйм, күз – күрә карауга, колак колакайга әйләнде. Адымнарым туры иде, атлавым чалшайды. Күкрәкне алга чыгарып көлгәнем булмады, уйларым каен сагызыдай каралды, тормышым тоташ җәһәннәмгә әверелде. Көчләп-көчләп өстәл янына утырып карыйм – баш барабандай буш, тегермән ташыдай авыр, иңнәремә утын әрдәнәләре өйгәннәр. Җилкә чокырымда – авыр сулар, күкрәгемдә саллы кувалдалар белән шакы-шокы таш ваталар... Йа Хода! Теге төндә, басым шашып сикергәндә, зиһенемне кара томан сарганда, сәбәбен бер үзем генә белдем, үзем генә! «Әле ярый, дөньяда акылны томалап, хәтерне үтерә торган аракы бар!» – дип, ялган юанган чакларым булмадымыни?! Нәкыя күрмәсен дип качып, чәркәгә баш органнарым әз булдымыни?!

Һәм мин, яклау эзләп, КГБга мөрәҗәгать итәргә булдым. Түбән чиннар, бүлек башлыклары мәсьәләне хәл итә алмадылар: Рәфыйковның агент булуы аларны тоташтан тыйлыктырып торды. «Язгыз,– диделәр алар,– әмма ләкин Рәфыйковның агент икәнлеген дөньяга чыгармагыз». Ниһаять, мине КГБ рәисенең урынбасары, Татарстан депутаты Сәлимов Венер Асылгәрәевич кабул итте. Чын итеп, аңларга ты-

рышып, ярдәмгә әзер булып ярты сәгатьтән артык тыңлады һәм: «Хаклыкны җиткерергә бик вакыт җиткән, Тавлинның теләсә ни лыгырдап йөрүенә чик куярга вакыт. Язучылар союзыннан вәкилләр килсен, Рәфыйковның эшен башыннан азагынача тикшерсеннәр һәм матбугат аша үз сүзләрен әйтсеннәр», – диде.

Һәм мин Г. Ахунов белән Р. Зәйдулланың, барып, «эш» белән ныклап танышуларын, тиешле бер нәтиҗә чыгаруларын үтендем...

Дөньяда хәбәрдән дә тиз йөри алган нәмәрсә юк! Алар КГБга барып кайтуга ук, Шамил Рәкыйпов шалтырата... эш дәвамында ялгышлар да ычкынгандыр, гафу ит, ди... Тавлинның соңгы вакытлардагы иң якын дусты, киңәшчесе Шамил каушаган! Минем күземә чалынмаган икән: кайсыдыр газетада Диләрә Зөбәерова[1] да миңа тибеп үткән икән! Каян, кем җиткерә, диген син аны, Мәҗитнең агент булуы да ул алкашның төссез йон баскан колагына барып кергән, диген. Шалтырата, авызы сасы кабахәтнең, ярым исерек, сүзенең элә-тотанагы булмаса да чамаладым: миңа ярарга тырыша. «Зәйнәп апаның көндәлекләрендә синең әтиең турында да язганнар бар», – ди. Архивында ниндидер кызыклы документлар, хатирәләр бар, имеш... «Мин шуларның һәммәсен дә сиңа тапшырырга телим», – ди, юхалана, боргалана. Мин аңышмый торам, Гариф искә алды: «Диләрә дә сиңа орып бәргән иде бит», – дип, эшкә ачыклык кертте. Инде, имгәтелмичә генә, Ркаил белән Гарифның мәкаләсе басылып чыкса...[2] Кайберәүләр пыяла ватыкларына басып сикергәлиләр булыр... Теләсә нишләсеннәр, алда миңа тынычлык килерме? Тавлин дигән кара йөз тынармы? Котылырмынмы мин итәгемә ияреп, сөйрәлеп килгән кара шәлдән?!

Көн кичкә авышты. Йөреп керәм, ашханәгә барам, уйларымны таралмасын өчен кысып кочаклап, ятагыма менеп ятам. Кештердәп торган ак җәймәләргә уралып җылынып

---

[1] Диләрә Гази кызы Зөбәерова (1930–2000) – язучы. ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1980).

[2] Ахунов Г., Зайдулла Р. Как родилась фальшивая легенда? // Вечерняя Казань. – 1992. – 14 октября. – С. 4. Мәкалә «Сайланма әсәрләр»нең 6 т. кертелде (2016, 677–680 б.).

яту рәхәт! Бүлмәмнең өч җирендә җемелдәп ут яна, уйларның яктыларын гына күңелемә чакыра алам. Әле Вахит[1] хакында уйлыйм...

Санаулы вә кадерле вакытын берчакта да исраф итми торган сабыр, юаш кыяфәтле бу кешенең көчле рухлы, нык холыклы, хөкем ярата торган серле вә сәер икәнен чамалый идем. Хәзерге заман – аның үз мохите, үз стихиясе.

Танышлыкның кайсыдыр бер баскычында адәм уллары белән тәмам аерылырга мәҗбүр ителәсең икән. Мин моны бүген Вахит-Аяз арадашлыгында ап-ачык күрәм. Адәм балалары танышларына чишә алырлык күңел серләрен бер-берсенә ачып бетергән. Мактанырлык казанышларны һәр ике як уртага салып, үзенең шәплеген кат-кат раслаган. Күргән-белгән вакыйгалардан хәтер сандыгында сакланганнары телдән телгә күчеп беткән. Чит адәмнәр язмышыннан гыйбрәткә ярарлык гамәлләр дә яшеренеп калмаган. Һәрберебез үзенә кулай, үзен югары һәм нык итеп күрсәтер дәрәҗәдә кылган яхшылыкларны түкми-чәчми сөйләп биргән. Бер-берсенә карата уйга килгән шик-шөбһәләрне чамалап кына телгә кертеп, бер-беребезне сынашулар булган. Табын уртасына аракы-коньякларны тезеп куеп, эчемлектәге гайрәтләрне тәртә арасына кертеп, үткәндәге мәйданнарда шактый нык, парлашып та, ялгыз-ялгыз да чабышылган. Уртак эшләр, уртак фикерләр, икенә дә килешерлек яшәү сәгатьләре булган, хатирәләргә ябышып – артка, хыялларга канат куеп, алга таба, ерак офыкларга да үтелгән. «Синнән килгән хатларны җыйган идем, бер том булырлык тупланды»,– дип язды Вахит соңгы хатында... Әнә шул, бергә тоташтырып торган төеннәр кинәт кенә чишелеп китә икән. Гаҗәп түгел! Моны, шушы «кинәтлек»не, ихлас ачылып яшәгән һәр пар кичерә, дип уйлыйм мин.

Бүгенге шартларда Вахит белән минем арада бер тамчы да уртаклык калмаган, без, язмыш дигән текә баскычның безгә багышланган уртак араталарына ябыша-ябыша, астан

---

[1] Вахит Мөхәммәтзакир улы Юнысов (1930–2006) – СССР дипломаты (илчесе), язучы. 1997–2006 елларда Мәскәү татар милли-мәдәни автономиясенең матбугат органы булган «Татарские новости» газетасында баш мөхәррир урынбасары булып эшли.

өскә дә, өстән аска да берничә тапкыр менеп төшкәнбез, үзебезне дә, уртаклыкны да кат-кат сынаганбыз. Хәзер беребез – өстә, икенчебез аста торып калган. Кем өстә, кем аста булуын ачыкламыйм, бәлки, без, Ходай кодрәте белән төп урыннарыбызны алыштырып, алмашкалап та торабыздыр, әмма без хәзер берчакта да, әллә нинди кодрәтләр иңсә дә, бер яссылыкта, бер буйда була алмыйбыз. Бусы – шиксез. Әгәр адәм уллары чынлыктан качарга, ачы хакыйкатьтән күзләрен яшереп калырга теләмиләр икән, билгеле бер вакыт үткәннән соң, табигатьнең аяусыз кануннарына буйсынып, һичшиксез, бер-берсеннән ерагаялар. Дуслыкның чиге күренми калмый. Дөрес, акылга ия затлар бу чарпаланышны, мондый аерылуны күренмәс дәрәҗәдә генә бер-берсенә игътибарлап саклый алалар, чит күзләр алар арасына кергән җилне абайламаска да мөмкин. Әйтик, ир белән хатын, озак еллар яшәгәннән соң, арада туган салкынлыкны, тушлый-тушлый каткан калын бозны да чит күзләрдән яшерә алалар ич! Ир белән хатын арасы – беркем акылы да ирешмәслек, бернинди зирәк тә чишә алмаслык серле табышмак ул.

«Бу араларда бер дә вакытым булмас, мин итальян, Америка бизнесменнары белән бергәрәк яшәргә тиеш»,– диде Вахит. Бәлки, хак та әйткәндер, әмма ләкин ул бу хәбәрне эчке бер сөенеч белән әйтте. Мин бу аерылышуны соңгы мәртәбә Казанда очрашканда ук сизенгән идем. Монда аның да, минем дә гаебем юк, бары тик шул аңлашыла: табигать һәрдаим бездән өстен, үзбаш уйларны ияртеп атлыйбыз дисәк тә, без искәрмәстән аның астыртын вә өстертен кануннарына баш бирәбез, буйсынабыз.

[...]

# Аяз Гыйләҗевнең әдәби тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләре

## Ә син үзең кем, укучы?[1]

*(Әхсән Баяновның[2] «Яшьлегемне эзлим» әсәренә карата)*

Безнең наширләр[3] җае чыккан саен мактанмый калмыйлар: «Казан нәшриятымы? РСФСРда өченче урынны алып тора ул! Мәскәү, Ленинград нәшриятларыннан гына калыша. Бездә өч көн саен бер әдәби китап басылып чыгып тора»,– диләр.

Күпме бу сан, өч көнгә бер әдәби китап? Бик күп.

Университетның фәнни китапханәсенең китап саклау залларына беренче мәртәбә кергәч, андагы байлыкны, Хеопс пирамидалары кадәр өелгән китап-журналларны күргәч, мин гаҗәп-хәйран калган идем. Казан наширләре әйткән сан әнә шул китапханәләрдә еллар, гасырлар буе тупланып килгән зур белем, иҗат байлыгы булганга күп. Бу байлык тулаем укучы кул астында: эзләп тап, укы, өйрән, ярат.

Хәзерге заман укучысы күп укыймы? Әйтик, авылларда сыер савучы кызлар елга ничә китап укыйлар? Укыганны хәтерлиләрме? Язучыларны беләләрме? Газета-журналларда басылган тәнкыйть-библиография материаллары белән кызыксыналармы?

Шактый укыйлар. Шул уңай белән бер мисалны хәтергә алып китәсем килә. Бер әбине беләм мин. Ул үз гомерендә ничә китап укыгандыр, әйтү кыен, әмма аңа иң-иң ошаган

---

[1] Мәкалә 1967 елда «Совет әдәбияты» журналында (№ 11) басыла.

[2] Әхсән Фәтхелбаян улы Баянов (1927–2013) – язучы. ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1988), ТРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1999).

[3] Нашир (гар.) – матбугат әсәрләрен бастырып чыгаручы.

китап «Моңлы хатын Бибигайшә»[1] исемле. Ул тора-тора да колак артына җеп белән бәйләгән күзлеген тартып куя, кадерләп кенә шул китапны ача. Бибигайшәнең ирсез, баласыз калуын тасвирлаган беркатлы, хәйләсез тарих һәрчак аның кадерле күз яшьләрен сытып чыгара. Әби башка китаплар белән бөтенләй кызыксынмый. Ул үзенә кирәкне эзләп, сайлап алган, моңлы хатын Бибигайшә тарихы аның рухи ихтыяҗын тулаем канәгатьләндерә. Әдәбиятның, эстетиканың бөтен нормаларын, бөтен кагыйдәләрен әби әнә шул китаптан чыгып белә. Шушы китап – аның эчке дөньясы, аның әхлак, эстетик үлчәве. Әби бу китапта язылган һәр сүзгә икеләнүсез ышана, аңа табына, әгәр китапны тәнкыйтьләп берәр сүз әйтсәң, бәбкәсен усалдан саклаган ана каз шикелле сиңа ташлана. Әдәбиятның «альфа» һәм «омегасы» – аның өчен шушы китап.

Гомумән, безнең халыкта элек-электән китап сүзенә, басма сүзгә икеләнүсез ышану, хәтта табыну яшәп килгән. Бу үз чиратында мөселман диненең догма булудан, китап – изге нәрсә, анда басылган тикшерелергә тиеш түгел, аны шиккә алырга ярамый, дигән аяусыз, ләкин, нигездә, караңгылыкка, наданлыкка этәрә торган законнардан килә.

Мөселман диненә кадәр үк язма сүзгә инану булган. Борын-борыннан «тузга язмаганны сөйләмә» дигәннәр. Димәк, тузга язмаган сүз әле дөреслек, хакыйкать түгел, тузга язылса – инде эш башка.

Хәзер дә бер иш талымсыз укучылар китапның һәр сүзен, ноктасын-өтерен бәхәссез хакыйкать, чынбарлык дип кабул итәләр. Аның «шагыйранә ялган» икәнен күп вакыт уйлап та бетермиләр. Моның ачык мисалын язучылар, редакцияләр ала торган күпсанлы хатларда күрәбез. Очрашуларда да тешне камаштыра торган традицион шушы сорауны биреп теңкәгә тияләр. «Фәлән хикәядәге төгән абый яки апа (болары – әсәрнең геройлары була инде!) хәзер кайда яшиләр? Алар очрашалармы?» – дип сорыйлар. Әсәрнең герое бер матур кыз икән, кызның адресын сорап йөдәтәләр.

Бу мәсьәләнең тагын бер кызык ягы бар. Сәхнәдә уйнала торган образларның-геройларның адресларын сорамый-

[1] Я. Мамишев поэмасы.

лар, аларны чын итеп кабул итмиләр. Аларны артист уйный, диләр. Сәхнәдә уен, тамаша бара, «ул тузга да язылмаган, ташка да басылмаган». Шуның өчен булса кирәк, драматурглар хатларны сирәгрәк алалар. Алган тәкъдирдә дә аларга «Сезнең пьесагызны каян табарга икән?» дигән эшлекле сораулар гына килә.

Әле күптән түгел генә Пермь өлкәсенең Барда районы Озынъялан урта мәктәбенең 8нче класс укучысы Нәсимә Мусинадан хат алдым. Ул болай дип яза: «Өч тәгәрмәчле арба»[1] исемле хикәягезне укыдым... Ни өчен сез Луиза белән Рәшатны аердыгыз? Соңыннан алар аңлашып кушылмадылармы?»

Укучыларның әдәби персонажларны чыннан да бар итеп, үз итеп, чын итеп кабул иткән очраклары аз түгел. Әйтик, Твардовскийның[2] мәшһүр Тёркины[3], атаклы солдат Швейк[4]. Мондый бәхетле очракларда язучы тудырган әдәби герой халык күңеленә шулкадәрле хуш килә, укучы аңардан башка яши алмый, аны үзенең көндәлек тормышында да юлдаш итә. Күп илләрдә халык арасына киң таралган әдәби геройларга һәйкәлләр дә куелган. Америкада Марк Твенның[5] геройларына һәйкәлләр бар[6]. 1966 елда «Литературная газета»

---

[1] А. Гыйләҗев хикәясе.

[2] Александр Трифонович Твардовский (1910–1971) – совет язучысы, 1950–1954; 1958–1970 елларда «Новый мир» журналының баш редакторы, Сталин (1941, 1946, 1947), Ленин (1961) премияләре лауреаты.

[3] Василий Тёркин, А. Твардовскийның «Книга про бойца» поэмасының төп герое.

[4] Чех язучысы Я. Гашекның «Похождения бравого солдата Швейка во время мировой войны» (1921–1923) романының сатирик герое.

[5] Сэмюэл Лэнгхорн Клеменс (1835–1910) – америка язучысы, журналист.

[6] 1926 елда М. Твен туган Ганнибал шәһәрендә (Америка) әдипнең геройларына – Том Сойер һәм Гекльберри Финнга һәйкәл ачыла.

Голландия, Делфзейлдә Ж. Сименон[1] романнарының халык яраткан герое Мегрэга[2] һәйкәл ачылуын язды.

Ләкин болар – икесе ике төрле күренеш. Беренче очракта без укучының әзерлексез булуын, әдәбият кануннарын, китапны беркатлы аңлавын күрсәк, икенче очрак укучыларның әдәбият белән тирәнтен кызыксынуларын, үз итеп, яратып яшәүләрен раслый.

Соңгы елларда безнең укучыларның да әдәбиятка ихтыяҗлары, таләпләре туктаусыз үсә, яшермим, мин дә Казан паркларының берендә үзебезнең мәшһүр шүрәлеләребезгә һәйкәл булыр, дип ышанам.

Хәзерге заман укучысы көн саен, сәгать саен кинотеатрлар, радио-телевидение, газета-журналлар аша әллә никадәр информация ала. Элекке укучы белән хәзерге заман укучысы арасында, аларның эстетик зәвыкларын билгеләгәндә, аерма гаять дәрәҗәдә сизелерлек. Әмма әдәбиятны бик примитив, гадиләштереп аңлау күренешләре адым саен диярлек очраштырып тора. Моңа сәбәп, бердән, безнең нәшриятларда, журналларда түбән зәвыклы, примитив әсәрләр басылып тору булса, бер иш тәнкыйтьчеләрнең (Ф. Мөсәгыйть[3], Х. Хәйри, яшьләрдән Ф. Мусин) шундый характердагы әсәрләрне күтәреп, мактап йөрүләре, шундый характердагы хикәя-романнарны ниндидер үзгәрмәс эталон итеп раслауларында. Болар барысы да – безнең укучыларның әдәби әзерлеге үсүгә комачаулый торган факторлар.

Әйтик, әдәби әсәрнең схемасы. Кире һәм уңай геройлар, бүленеп, каты бер принцип белән тамгаланып куелганнар. Бер якта уңай геройлар, икенче якта – киреләр. Уңай герой эчми-тартмый, гел яхшылык эшләп йөри, акыллы сүзләр ычкындыра, һәйбәт, кешелекле. Кире герой боларның нәкъ киресен эшли: сүз тыңламый, аракы да йоткалый, акны – кара, караны ак дип ышандырырга азапланып йөри. Нәтиҗәдә...

---

[1] Жорж Жозеф Кристиан Сименон (1903–1989) – күренекле язучы, детектив романнар авторы.

[2] Комиссар Жюль Жозеф Ансельм Мегрэ, Ж. Сименон детектив романнарның төп герое, полицейский. 1966 елда Голландиянең Делфзейл шәһәрендә комиссар Мегрэга һәйкәл ачыла.

[3] Фатих Шәрәф улы Мөсәгыйть (1903–1990) – тәнкыйтьче.

анысын барыбыз да китапны кулга алуга ук беләбез: әйе, әйе, уңай герой тегене җиңеп чыга!

Бик гади һәм җайлы схема. Язучылар өчен дә, укучылар өчен дә, тәнкыйтьчеләр өчен бигрәк тә. Барысы да урынында, сарык та исән, бүре дә тук. Схема әзер, техник контроль бүлегендә утыручы иптәш кебек шул стандартны тотасың да шап-шоп үлчисең. Иңе-буе, авырлыгы, метры метрга, җеге җеккә, җебе җепкә туры киләме? Килми икән, «шалт» авторның башына берне! Моннан болай тыңлаусыз булмасын, бозмасын кемнәрнеңдер тынычлыгын.

Әсәрдәге персонажларны шулай аерып йөртүче тәнкыйтьчеләр язучыларны да шулай икегә бүлеп йөртәләр. Берәүләрне сыйпап-сыйпап иркәләргә яратсалар, икенче берәүләр туктаусыз дөмбәсләү тоеп яшиләр.

Примитив әсәрләрнең иң куркыныч яклары шунда: алар укучыда уйлау сәләтен үтерәләр, һәрвакыт, һәрчак әзер стандарт фикер сеңдереп киләләр. Тормыш-көнкүрешләренә, җәмгыять үсешенә җентекле күз белән карау сәләтен үтерә андый арзанлы әдәбият. Кешеләрне гражданнар түгел, тыңлаучан гади винтиклар булырга мәҗбүр итә. Әдәбият барыннан да элек хөр фикерле гражданнар тәрбияләргә тиеш.

Мондый беркатлы аңлатулар, примитив рәвештә язучыларны төркемнәргә бүлүләр, язучының шәхси мастерлыгын, индивидуальлеген ачарга, аңларга комачаулый. Укучылар да, шуңа ияреп, стильләре, дөньяга карашлары бөтенләй ошамаган язучыларны әлеге дә баягы яманаты чыккан төрләнеш буенча аерып йөртә башлыйлар. Кай очракта бу — аларның мәхәббәтләрен яки нәфрәтләрен дә билгели. Язучының стиль үзенчәлеген тою исә — укучының югары культурасын, әзерлеген раслаучы факт. Аңарда бу нечкәлекне бер яктан язучы үзе тәрбияләсә, тәнкыйтьче монда турыдан-туры ярдәмче була ала.

Төрле-төрле иҗат алымнары белән эш итә торган, һәр оста язучының үзенә генә хас «һөнәр сере» барлыгын укучы ап-ачык аңларга тиеш. «Казан утлары» журналы менә ике ел инде «Укучылар сүзе» дигән бүлегендә ифрат кыйммәтле һәм шиксез файдалы эш алып бара. Бик кирәкле, гыйбрәтле һәм файдалы бүлек бу! Анда капма-каршы фикерләр, бәхәсләр,

шикләр, мактаулар, усал-усал тәнкыйть сүзләре дә янәшә урын алалар. Бик дөрес! Югыйсә минем бер әсәрем турында газетада ике төрле фикер басылып чыккач, кайберәүләр чын күңелдән: «Ничек инде бер үк газета, бер үк әйбер турында капма-каршы ике фикер язып чыга?» – дип бик сәерсенгәннәр иде.

Бусы кызганыч. Мондый фикер әйтүчеләр, газетаны укучы меңнәрчә кешеләр бертөрле үк фикер йөртергә тиеш, дип уйлыйлар микәнни? Ни өчен бер әсәр бөтен кешегә дә ошарга яки ошамаска тиеш? Һәркемнең дә үзе генә яраткан җыры юкмыни?! Нигә тырышып-тырышып, көчләп, укучыларны нәкъ бертөсле фикергә табындырырга?

Әдәбият, бигрәк тә аның тәнкыйть өлеше укучыда үзбаш уйлау сәләте үстерергә тиеш. Тузга язылган сүзләр күп, ташка басылган сүзләр күп, әмма хакыйкать бер генә. Социалистик реализм методының чикләнмәгән мөмкинлекләре бар, шул мөмкинлекләрдән юмарт файдаланырга гына кирәк. Хакыйкатьне, дөреслекне укучы үзе эзләп табарга да өйрәнсен. Хәзерге укучының күп өлешендә моның өчен әзерлек тә, тәҗрибә дә җитәрлек. Аны көчләргә ярамый. Һәрбер әдәби китап табыну, инану өчен түгел, уйлану өчен! Югыйсә бик фаҗигале хәлләр дә булып ала.

1966 елның көзендә Казанда республика Үзәк китапханәсендә укучылар белән очраштык. Шул күңелле мәҗлестә Мөслим районында 10нчы классны тәмамлап килгән, хәзер университетның филология факультетында укучы студент чыгыш ясады. «Яхшы әсәрләрне ничек инде журналда тәнкыйтьләргә мөмкин?!» – диде ул, бик ачынып. «Менә без, унынчыда укыганда, Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр»[1] романы буенча укучылар конференциясе үткәрергә әзерләнә идек. Нәкъ шул чакта журнал битләрендә романга тәнкыйть сүзләре басылды. Без ни әйтергә дә белми аптырап калдык, укытучыбыз да югалып калды. Конференцияне үткәрә алмадык, өзелде».

Мин бу чибәр егетне бик кызгандым. Гомумән, мәктәптә бу укытучыдан әдәбият дәресләре тыңлаган укучыларны кызгандым. Алар шулай, һәр басылган, китап битенә кер-

[1] Г. Әпсәләмовның 1965 елда язылган романы.

гән сүзләргә инанып, колларча табынып киләләр микәнни? Әллә инде Г. Әпсәләмов бер чакта да тәнкыйтьләнергә тиешле түгел дип уйлыйлармы?..

Укучылар романны укыганнар, яратканнар. Бик әйбәт, бик табигый, чыннан да, һәйбәт роман! Әгәр бу – шулай икән, роман укучыларда яхшы тәэсир, матур уйлар тудырган икән, һәм алар моңа нигезле рәвештә инаналар икән, журналда басылган тәнкыйть сүзләре аларда бәхәс уятырга тиеш иде. Алай булмаган, кызып-кызып романны мактарга әзерләнеп йөргән укучылар суга төшкән тавык кебек җебеп калганнар. Юк, мин аларга ышанмыйм, романны да, Әпсәләмовны яратуларына да бик шикләнәм, кирәк чакта хак сүз өчен канга-кан килеп сугышачакларына да ышанмыйм. Ышанасың икән, инде ахырынача үз сүзеңдә тор! Үзең тапкан, тормышта кыйнала-кыйнала, сөелә-сөелә үзең сайлаган хакыйкатьне көн саен алыштырып булмый. Дөньяга караш, кешелеккә караш, өстәге кием кебек, сезонына карап алышынмый. Мин сукыр рәвештә, фанатикларча ышану турында түгел, аңлы-дәлилле рәвештә ышануны күз алдында тотам.

Китаплар күп басылып чыга. Күп булсалар да, алар төрле-төрле. Укучылар да төрле-төрле. Укучы бөтен басылып чыккан китапларны укып бетерә алмый. Һәркемнең үзе генә яраткан язучысы була. Әгәр бу шулай икән, укучы киң күңелле булырга да тиеш. Ул башка авторларның хезмәтенә дә (сүз чын язучылар, каләм мастерлары турында бара) хөрмәт белән карый белсен. Ул бәхәсләрдә түземлелек, такт күрсәтсен. Ләкин бездә еш кына алай булмый. Безнең нәни генә булса да диктатор буласыбыз килә, безгә ошаганны гына, мин яратканны гына! Башкалар бар да – чүп, кәгазь буяучылар гына!..

Мәдинә Маликованың «Казан утлары» журналының 8нче санында басылган «Кем ул Әнис Бадигин?» дигән мәкаләсе дә әнә шундый ашыгыч кискенлек, диктаторлык рухы белән сугарылган. Укучы Әхсән Баянның повестен укып чыккан да, кайнарланып, күсәкнең иң зурысын элдергән һәм, абайламыйча-нитмичә, табаларга керешкән.

М. Маликованың җенен иң нык кузгаткан мәсьәлә Ә. Баянов повестенда[1] бирелгән хатын-кыз язмышы. Тәнкыйтьләүче иптәш «Яшьлегемне эзлим» повестендагы Лена, Фәһимәне үз канаты астына алып, очынып-очынып мактый, повестьның героен һәм бер уңайдан авторын да «зур гөнаһлар»да гаепли.

Чыннан да бу – шулаймы? Ә. Баянов, хатын-кыз образларын тудырганда, тарихи дөреслеккә, логикага, әдәбият кануннарына хыянәт иткәнме? М. Маликованы иң-иң кыерсыткан мәсьәлә дөрес хәл ителмәгәнме? Ул тырышып-тырышып яклаган, бизәгән Лена – яхшы холыклы, чая һәм әйбәт кешеме?

Повестька мөрәҗәгать итик.

Менә Лена белән танышабыз...

Ояда кош балалары авыз ачып утыралар. Әнис бер кошчыкны тотып ала да һавага чөя, тагын берне, тагын берне... Ни өчен? Кем өчен?.. Бу кыланчык үсмернең үз фәлсәфәсе, куркыныч фәлсәфәсе яралып килә. «Көчсезләрне рәнҗетүдән куркырга ярамый!»

Шушы фәлсәфәнең туып килүенә, бичара кошчыкларның һәлак булуына шаһит Лена чын күңелдән эче катып көлә, Әниснең егетлегеннән күреп соклана...

Менә Лена укырга шәһәргә килә. Юк, мескен бер авыл кызы булып түгел, яулап алучы булып килә! Чөнки аның абыйсы шушы шәһәрдә Министрлар Советында эшли. Властьның тәмен татып бозылырга өлгергән кыз булып килә. Ансат кына укырга урнаша, чөнки «авылдан отличник документлары табып килгән». О-о, авылда да Ленаның абыйлары, апалары бар икән ләбаса!.. Менә Лена Әниске гашыйк була, артистлар сыман башын артка җибәреп, үзенең мәхәббәтен белдерә. «Мин бик көнче. Кара аны, мин сине беркемгә дә бирмәячәкмен»,– дип кисәтеп куя.

Әниснең кая укырга керүен дә, асылда, Лена хәл итә. Кыз өчен аның кайда укуы да, кем булуы да мөһим түгел, тик Әнис аның белән генә калсын, вакыты килер, ул аннан абыйсы кебек үк могтәбәр әһел ясаячак. Үзенең укырга сәлә-

---

[1] Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим» (1966) повесте турында сүз бара.

те юк икән, тиз генә мәктәбен ташлый да ансат кына эшкә дә урнаша.

Шәһәр Әнисне куркыта, ул югалып кала, авылга борылып кайтырга уйлый. Аның юлын Лена кисә: «Җүләр… тапкансың выход»,– ди һәм үз юлын тәкъдим итә. «Әйдә өйләнешәбез!» Лена – батыр, көчле, ул бер почмактан икенче карангыга Әнисне сөйри.

Үзләренә квартир кирәк булгач, анда яшәүчеләрне куып чыгарачакларына Әнис шикләнеп тормый инде. Чөнки ул Ленаны җитәрлек күрде, байтак сынады. «Лена тотынса… ул аны башкарып чыга да чыга инде»,– дип уйлый ул.

Һәм чая Лена, акыртып-бакыртып, кыш уртасында квартирантларны урамга кудырта. Туй дип атала торган фарста Әнис эчеп исергәч, Ленаның үз якыннарыннан берәү, Ленаны һәм аның мохитен яхшы белүче акыллы кеше, җан ачысы белән: «Нинди яшь малайны харап иткәннәр!» – дип куя.

Тормыш исереклеге дә, хәмер пары да миенә йөгергән Әнисне бу сүзләр сискәндереп җибәрәләр, әмма ул үзе кереп капкан читлекне ватып чыгарлык хәлдә түгел. Ул чыннан да көчсез, ихтыярсыз. Ул пассив рәвештә уйлана. «Кайчандыр җанымны үземнеке иткән Бетховен инде миннән читләште бугай» дип, җанының күгәрек белән каплануына ачынгалый да. Ләкин сүздән эшкә, хәрәкәткә күчә алмый.

Сөяме Лена Әнисне? Фәһимә аны ярата мы? Валя, тагын бик күп кызлар, барысы да, үлеп, «Әнис!» дип өзелеп торалармы?

Сөйми Лена Әнисне! Ул аны эзләп таба, кулына ала һәм бәйдәге көчегенә әйләндерә. Фәһимә дә сөйми Әнисне, Валя да, башкалар да.

М. Маликова бер нәрсәгә игътибар итмәгән. Повестьта телгә алынган Әнис Бадигинга нindидер мөнәсәбәттә булган кызлар барысы да яшь ягыннан аңа караганда олыраклар, мәхәббәттә алар тәҗрибәлерәк, акыллырак. Шуның өчен дә активлык кызларның үз кулында. Фәһимә дә, Лена да, Валя да Әнисне үзләре сайлап алалар, беренче булып сүз каталар, мәхәббәтләрен белдерәләр. Техникумда укыганда, мәхәббәт тәкъдим итеп, Валя аңа хат яза. МТСтан ашлык кабул итәргә килгән кыз да Әниснең күңелен яулап алырга тели.

Бу ни хәл? Кайда соң татар кызларының атаклы тыйнаклыгы, сабырлыгы? Менә монда без катлаулы тормыш фаҗигасе белән күзгә-күз очрашабыз. Леналар, Фәһимәләр яратырлык егетләр барысы да фронтта. Авылда Әнис кебек яшь әтәчләр «дефицит булып калганнар». Буй үскән, акыл үсмәгән. Әнис – музыкаль малай, шуның өчен кызлар ихтыярсыз аңа тартылалар. Тартылучылар арасында Лена кебек әрсезләр дә, Фәһимә кебек тыйнаклары да бар. Үз ишләреннән, егетләреннән аерылып калган, сөяргә-сөелергә өлгермәгән яшь күңелләр, кая барып бәрелергә белмәгәч, аптырагач, әнә шул Әнискә барып бәреләләр! Бу – шул чорның иң кырыс дөреслеге. Лена үз планнарында чая, кыю булса, Фәһимә гүзәл, тыйнак һәм аз сүзле. Ул Әниснең бала-чага икәнлеген, яратуның нәрсә икәнен дә аңламавын бик яхшы төшенә. Болынга, яхшы атка утырып, колхоз председателе килә һәм Әнисне үзе белән кайтырга чакыра. Әле генә гыйшык уты белән исереп йөргән, төрле уйлар уйлаган Әнис, Фәһимәсен дә, мәхәббәтен дә онытып, председатель атына утырып кайту ягын каера башлый. Мескен малай! Сизгер Агыйдел кызы Фәһимә барысын да аңлый. «Эх син, юньсез малай! Бер тиенлек акыл да юк синдә. Бер тиенлек тә!» – ди.

Фәһимәнең Әнис белән мавыгуы – әсәрдәге иң көчле, иң фаҗигале урыннар. Фәһимә, очраклымы, әллә алдан уйлапмы, атылып үлә. М. Маликова хөкем чыгарырга да өлгерә: Фәһимәнең үлемендә, аз да түгел, күп тә түгел, Әнис кенә гаепле. Лենаның фаҗигасендә дә Әнис кенә гаепле.

Хәлбуки Фәһимәнең һәлакәте күп тапкырлар тирәнрәк, ул шушы җебегән егет өчен үлми, тормышның чәбәләнгән юлларында туры юл таба алмыйча үлә.

Лена турында югарыда әйтеп киткән идем инде.

Кем соң ул Әнис Бадигин үзе? Каян килеп чыккан ул хәзерге заман усалы?

Авыл малае. Табигать аңа матурлыкны тоюны, музыкаль сәләт биргән. Аңа уналты яшь. Ул өченче елын инде печән чаба. Унөч яшьтән кырда, болында эшли. Чөнки сугыш еллары. Аның без белгән тормыш өлеше шактый мәгънәле башлана. Ул үз баянында да кешеләрдән куркып кына уйнарга, яшеренергә мәҗбүр. «Курку гадәткә кергән»,– ди Әнис бер

урында. Куркак кеше хәрәкәткә, көрәшкә сәләтсез була. Бу – мәгълүм нәрсә. Ләкин Әнис әле алга талпына. Музыка мәктәбендә укыйсы килә. «Мин шунда укыр идем», – ди. «Менә син кая сикермәкче. Авылда андый мәктәпләр юк». Уналты яшьлек үсмер моның белән килешергә теләми. «Ә ни өчен юк?»

Бу гаделсезлек аның җанын әрнетә, гомумән, авылдашларының яшәеше, көнкүреше аны канәгатьләндерми. Кибән башына менгән Тимербикә апасыннан ул: «Әйт әле, син анда басып торганданиләр күрәсең, ниләр уйлыйсың?» – дип сорый. Омтылышсыз, җансыз Тимербикә аның ачуын чыгара. Ул Тимербикәләр мохитен «ыргылып, сикереп үтәргә» тели. Фәһимә дә: «Мин каядыр китәчәкмен!» – ди.

Әле тормыш та, эш тә матур Әнискә. Юк, Мәдинә Маликова әйткәнчә, повестьның баш өлеше Ә. Баянов аерым талант күрсәтеп язганга түгел, әле үсмернең тормышы матур, тирә-ягы матур. Ул әле әкиятләр, хыяллар дөньясында яши, аның тирә-ягы ал да гөл. Әле үзенең көчсезлеген, гариплеген аңлау өчен, аңа күпне күрергә, күпне кичерергә туры килер. Нишлисең, шушы тынгысыз Әниснең яшәү юлы матур гына бармый, ул күңеле эзләгән кешеләрне очратмый, шәһәргә барып, бик начар средага эләгә. Шуның белән тиз ризалаша, үзенең яшьлек хыялларына гаять тиз хыянәт итә, көрәшми, рухы сына, бер-бер артлы кешелек моралենә хас булмаган тупаслыклар эшли. Квартирадан куып чыгарылган Шаһиәхмәтовны тотып тукмый... Болай гына, эш, сүз арасында егетлек дәрәҗәсен саклап калу өчен генә. Кош балаларын кырганда шаркылдап көлгән Лена ир кешене тотып кыйнаганда нәрсә уйламас! О-о, егет икәнсең син Әнис Бадигин, дияр! Заман, Леналар кавырсыны катмаган, дөньяга карашы ачыкланмаган бу үсмерне ялган егет ясыйлар һәм бөтен тормышын гарипләндерәләр. Әнис Бадигин, М. Маликова раслаганча, Агыйдел буенда пешеп чыгып, Уфа урамнарына килеп урнашкан усал түгел. Ул безнең күз алдыбызда акрынлап-акрынлап үзгәрә, түбәнгә тәгәри.

Ләкин бит повесть бер Әнис Бадигин турында гына түгел! М. Маликова әсәрнең Әнис Бадигиннан башка якларына бөтенләй игътибар итми. Әгәр әсәр нибары шушы пешмәгән

үсмернең мәхәббәт маҗараларыннан гына торса һәм нибарысы аның төпсез эгоизмын күрсәтүгә генә корылган булса, повестьның бәясе бик чамалы булыр иде. Дөрес, автор, «лирик повесть» дип, әсәрнең жанрын дөрес билгеләмәгән һәм, гомумән, мәхәббәт линиясенә артык зур игътибар биреп, кирәкле-кирәксез фәлсәфи чигенешләр белән мавыккан, тормыш тасвирларын саранландырган. Ләкин автор теләгәнме-теләмәгәнме, әсәр бер Бадигин турында гына түгел, ул үзе язган чорга шактый оста итеп кергән.

Кызлар һәм Әнис язмышында автор кырыс дөреслек ягында, дигән идек без. М. Маликова исә стандарт, барыбызга да мәгълүм төче дөреслекне таләп итә. Һай, Әнис консерваторияне алтын медаль белән бетереп, Фәһимәгә, йә булмаса, Ленага өйләнеп, атказанган артист булып китсә, бала-чагалар үстереп, Агыйдел буенда карлыган җыеп кына яшәп китсә, нинди гүзәл булыр иде канә! Тик тормыш берәүгә дә стандарт тормыш юлы әзерләп куймаган, тормыш законнары күптән мәгълүм булсалар да, һәр буын, һәр кеше аны үзенчә ача. Берәүләр бу яшәү юлында чыныгалар, җәмгыять өчен файдалы кеше булып китәләр. Икенче берәүләр сыгылалар, һәм җәмгыять алар турында үзе кайгыртып яшәргә мәҗбүр була. Әнис тә шундыйлардан. Дөрес, ул ахырында авылына кайта, эшли, комсомол оешмасы җитәкчесе булып сайлана. Ләкин аның канаты сынык, ул бик югарыга үрләгән, әмма оча алмаган, уртакул кеше булып яшәү аңа күңел рәхәте бирми. Нишлисең, әгәр шулай яшәсә, Әнис Бадигин әле бер генә абынмас, яшәү мәгънәсен нindидер шаккатризмнарда түгел, гадилектә һәм тырыш хезмәттә икәнлеген аңлар. Аңламый икән, гомере буе сөрлегеп, кыйналып яшәргә мәҗбүр булыр.

М. Маликова Бадигинга приговор арты приговор чыгарып, аны иң каты җәзаларга хөкем итсә дә, әсәр үзенең мәгънәви эчтәлеге, тормыш күренешләренә үтеп керә алуы белән кыйммәтле.

Мин дә яратмыйм Бадигинны! Аның Шаһиәхмәтне куып чыгарганда бөеренә таянып гаярьләнеп торуын күз алдына китереп, йодрыкларым йомарлана! Нәфрәтләнәм, күралмыйм. Ләкин бу – тормыш. Чынлык. Бар бит, Леналар да,

ларның абыйлары да, аларга «койрык болгап» киткән Бадигиннар да бар!

Автор бит Әнис Бадигинны үзенең идеалы, уңай герое, үзе безнең чынбарлыкта күрергә теләгән кешесе итеп тәкъдим итми. Монда бер «ләкин» бар... Әсәрнең башындагы катлы-катлы кереш сүзләр, томанлы эндәшләр, ятышсыз кинаяләр Маликованы буталышка этәргәннәрдер? Әхсән Баяновның иҗатында шундый кирәкле-кирәксез жестларга хирыслыгы бар. Әсәрнең башындагы кереш сүзләр, ят, кирәксез мотивлар. Бу кереш сүзе Лермонтовның «Безнең заман герое»на[1] охшарга тырышуы гына. Әсәр ахырындагы Агыйдел симфониясенең үлүенә офтанулар да Экзюперины хәтерләтәләр. Мондый тышкы охшашлыклардан повестьны арындырырга кирәк булган.

Журналда әсәрне беркадәр «төзәтеп» басканнар сыман.

Кыскартып, мәгънәгә зарар килгән урыннар да бар. Бадигинның хаклык эзләп Кавказга сәяхәт ясавы аңлашылмый калган. Милиционерның да ни өчен Әнисне үз итүе, яратуы, ярдәм кулы сузуы ышандырмый. Ләкин әсәрнең күңелне тетрәндерерлек урыннары, тормыш дөреслеген мастерларча ачып салган битләре бик күп. Үтә каршылыклы Сафуан образы. Бер яктан, башак эзләп, хатын-кызларның итәк асларын актара. Икенче яктан, игеннәрне кызганып, трактор тәгәрмәче астына ята... Ә теге акылдан язган, сәке астына кереп яткан Хәтирә!.. Шул Сафуан бит инде аның котын алган кеше... Шул ук Сафуан, үзен үзе аямыйча, эштә янып үлә... Нинди каршылыклы, катлаулы бу «тормыш» дигәнең!

Иркәлеккә караганда катылыкны күбрәк күргән Әнис Бадигинның сынып төшүе күпләргә гыйбрәт. Кеше акылы белән генә, кеше ихтыяры белән генә яшәмә. Җирдәге үз бәхетең өчен, халык бәхете өчен нидер эшлә, тырыш, көрәш. Югыйсә гомерең буш, куанычсыз булыр. Повесть әнә шул турыда да сөйли.

М. Маликова исә әсәрнең бу якларына бөтенләй игътибар итми, ул үзенең кәефенә ошамаган өчен, повестьны бер кизәнүдә юкка чыгара. М. Маликова француз мәкальләре

---

[1] «Герой нашего времени» (1838–1840), М. Ю. Лермонтов романы.

белән таныш икән. Ул аларның берсен бик оста һәм урынлы куллана. Мин аңа шулай ук киң таралган икенче бер француз мәкален исенә төшерер идем. «Бала коендыргач, ялгаштагы су белән баланы чыгарып түкмә»,— диләр.

Әхсән Баянов тигез генә атлап бармый. Ләкин ул — соңгы ике-өч ел эчендә әдәбиятның төп көчләренең берсенә әйләнгән талантлы язучы. Шуның өчен без, бала коендырабыз дип, баланы да тәрәзә аша түкмик инде. Сабыр, акыллы һәм уйчан булыйк. Әсәрне укыгач, кулга каләм алырдан элек, әсәр турында да, үзебез турында да уйланыйк. Шул чагында гына без әдәбиятыбызның иртәгәге көне өчен тыныч һәм ышанган булырбыз.

*1967*

## Халыклар күңеленә үтеп керик[1]

*(Радиочыгыш)*

Әдәбиятның кеше күңеленә тәэсир көче чиксез бер дәрәҗәдә. Кайнар хис, чынлык, матурлык тойгылары, алдынгы идеяләр белән сугарылган китаплар кеше хәтерендә гомер-гомергә якты истәлек булып саклаunion. Яхшы әсәр укып чын язучы белән танышу — бәхетле минутлар. Моннан берничә еллар элек Мәскәүдәге бер укытучыма үземнең моңарчы Герценны укымаганлыгымны әйткән идем. Ул, чын-чынлап көнләшеп: «Нинди бәхетле минутларың алда әле синең!» — дигән иде.

Без, татар язучылары, киң илебезнең төрле-төрле почмакларында булабыз, төрле катлау, әзерлек дәрәҗәләре төрле, бер-берсенә охшамаган укучылар белән очрашабыз. Бишәралтышар йөз кеше керерлек шыгрым тулы клублардагы кешеләрне очрашу минутларында бер хис, бер уй берләштерә: алар әдәбиятка — кешене кеше итә торган гүзәл могҗизага гашыйклар. Шул чакларда үзеңнән алда яшәгән язучыларга, шагыйрьләргә, тапкыр сүз осталарына рәхмәт тойгысы уяна. Алар бит инде безнең бабаларыбызны, аталарыбызны,

[1] Халыклар күңеленә үтеп керик. А. Гыйләҗевнең радиочыгыш өчен 1967 елда язган материалы. 6 т. «Сайланма әсәрләр»енең 2 т. басылып чыкты (2014, 272–279 б.).

чордашларыбызны матурлыкны яратырга өйрәтеп калдырганнар! Алар бит сыгылмалы матур ана телебездә кешеләргә яшәү хикмәтләрен сөйләгәннәр. Моңайган чакларда да, шатлык эзләгәндә дә, нәфрәт кичергәндә дә, җиңгәндә дә, җиңелгәндә дә кешеләр янына алар килгәннәр, яшәү законнарын, тормыш кануннарын тере образлар аша аңлатып биргәннәр.

Ләкин кешенең табигате шундый, ул кайчандыр үткән заманнардагы кешеләрнең ничек яшәүләре, ничек көрәшүләре, яратышулары турында гына белергә теләми. Аның үзе тудырганны, үзе катнашкан вакыйгаларны китаптан укыйсы, сәхнәдән карыйсы килә. Укучы үзе күргән вакыйгаларга, үзе белгән чорга активрак карый, аның китапларда яки сәхнәләрдә бара торган чордаш вакыйгаларга үз мөнәсәбәтен белдерәсе, катнашасы килә. Бүгенге көн язучыларына әнә шул табигый ихтыяҗны канәгатьләндерергә тырышу, бүгенге көн геройларын иҗат итү, аларны көндәлек тормышыбызда укучыларыбызның якын иптәше, киңәшчесе, сердәше итәрлек дәрәҗәгә җиткерү бурычы куелган.

Быел Бөек Октябрь революциясенә 50 ел тула. Бу – тарих өчен бик кыска, әмма безнең барыбыз өчен дә бик озын, вакыйгаларга бик бай вакыт, безнең илебездә моңарчы тарихта күрелмәгән, күзәтелмәгән, өйрәнелмәгән өр-яңа тормыш шартлары, мөнәсәбәтләр тудырды. Безнең илебез социаль төзелеше белән дә, географик ягы белән дә, милли составы чуарлыгы ягыннан да башка бөтен илләрдән аерылып тора.

Әдәбият, башка бик күп бурычлары белән беррәттән, әнә шул төрле-төрле халыкларны бер-берсенә якынайта, таныштыра, аларда дуслык, туганлык хисләре тәрбияли. Бу – аның иң изге бурычларының берсе. Һәм иң олы бурычларының берсе, дип тә өстәр идем мин. Әдәбиятның көчен бу өлкәдә һич бәяләп бетерерлек түгел. Әдәбият – шагыйрьләр, язучылар сүзе – илләр, чикләр аша үтә, дөньяның барлык почмакларына барып җитә. Димәк, әдәбият тормышыбызның гүзәл бер максатын – халыклар туганлыгына юл ачарга, аны ныгытырга тиеш.

Соңгы елларда бөтен җирләрдә танылган кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматов мисалын гына алыйк. Бу язучыга кадәр

без Кыргызстан тормышы, кыргыз халкы, аның көнкүреше турында күп нәрсә белә идекме? Әйе, еракта, Ала-тау тирәсендә, Кыргызстан дигән республика бар. Тау елгалары, далалары, далада көтүлекләре... Очраклы рәвештә радиодан көй-музыкаларын тыңлыйбыз, кулга төшкән китаплардан тау легендаларын укыйбыз. Менә берзаман безнең аңыбызга, акылыбызга, тормышыбызга гаҗәп көчле таланты, бай теле белән яңа рәссам, яңа кеше, яңа язучы килеп керә дә безнең яңа пәйгамбәребезгә әверелә. Без үзебез өчен моңарчы чак кына шәйләнгән яңа кешеләр, яңа җир, табигать, яңа мөнәсәбәтләр, кыскасы, тулы бер байлык ачабыз. Без кыргыз кызларының ничек горур булып ярата алуларын беләбез. Бу – Җәмилә[1]. Без кыргыз ананың ни дәрәҗәдә акыллы, тирән фикерле, хискә-моңга бай, мәхәббәтле икәнлеген күреп сокланабыз, безнең күңелләрдә яхшылык, туганлык, теләктәшлек хисләре уятучы бу чал ана алдында тетрәп калабыз. Бу – «Анам кыры»ннан[2] Тулганай. Безнең аңыбызга караңгы кыргыз далаларына нур алып килгән беренче мөгаллим Дүшән[3] онытылмаслык эз сызып уза. Сөбханкул, Алтынай, Алиман, Гүзәл, Әсәл, Байтимерләр безнең гомергә онытылмаслык дусларыбызга, танышларыбызга әвереләләр. Бер язучы үзенең көчле рухы белән безне никадәр баетты, безнең күңелләрдә үзенең туган халкы – кыргыз халкына мәхәббәт тудырды. Чыңгыз Айтматовның соңгы әсәре исә – «Сау бул, Гөлсары!»[4] повесте – безнең акылыбызга яктылык, нур өстәде, безне уяныргa, уйланырга мәҗбүр итте. Аның Танабае, гади бер көтүче булса да, безнең илебездә булып узган катлаулы вакыйгаларга җавап бирә алды.

Күрәсезме, бер язучы – үзе бер дөнья. Чыңгыз Айтматов, әнә шул безнең өчен яңа дөнья – Кыргызстанны, аның яңа кешеләрен ачучы буларак, Җир шарын әйләнеп чыкты. Яратасыңмы-яратмыйсыңмы син ул тудырган дөньяны, ирек сөюче тырыш кыргыз халкын тарих битеннән сызып

[1] Ч. Айтматовның «Җәмилә» (1958) повестенда төп героиня.

[2] Ч. Айтматовның 1962 елда язылган повесте.

[3] Ч. Айтматовның «Беренче укытучы» (1962) повестенең төп герое.

[4] Ч. Айтматовның 1962 елда язылган повесте.

ташлый алмыйсың. Язучы үз иҗатында халыкның тарихын, яшәешен, көнкүрешен мәңгеләштерде. Менә нәрсә дигән сүз ул – әдәбият, менә нәрсә дигән сүз ул – язучы.

Без Чыңгыз Айтматов иҗаты белән рус теле аша таныштык. Илебез халыкларының талантлы вәкилләрен әнә шулай таныштыра торган мактаулы миссиясе дә бар аның – рус теленең. Шуның өстенә рус теленең безнең өчен, рус булмаган милләтләр өчен, икенче ягы да бар. Без, рус теле аркылы дөнья әдәбияты вәкилләре, төрле илләр, төрле халыклар белән танышу өстенә, үзебез дә шул тел аша, шул әдәбият аша ил күләменә, дөнья мәйданына чыгарга тиешбез.

Әйтергә кирәк, бу өлкәләрнең икесендә дә без җитәрлек дәрәҗәдә эшләмибез. Бу турыда безгә кат-кат уйланырга һәм җитди борылыш ясарга кирәк.

Мин үзем унбиш яшемә кадәр русча белми идем. Мин Пушкинны, Лермонтовны, Горькийны иң элек татар телендә укыдым. Рәхмәт тәрҗемәчеләргә, мин бу бөек язучыларны башка бик күп китаплар арасыннан аерып ала алдым, яраттым. Хәзер дә әдәбиятны татар телендә генә укучыларыбыз бик күп. Ләкин тәрҗемә китапларын чыгаруны без елдан-ел киметә барабыз. Хәзерге заманның – егерменче гасырның иң атаклы прогрессив чит ил язучылары Хемингуэй, Ремарк, Фолкнер, Экзюпери, Генрих Белль әсәрләре татар укучысыннан бөтенләй читтә торалар.

1963 елда Париждагы иң зур китап кибетенең хуҗасы «күп укыла торган язучы кем икән» дип кызыксынган һәм махсус тикшерү үткәргән. Иң күп укыла торган язучы-философ һәм уйлап табучы, Франциянең милли герое, немец фашизмына каршы көрәштә һәлак булган атаклы язучы Антуан де Сент-Экзюпери булып чыккан. Бүгенге көн әдәбиятына, халыклар аңына, бик күп язучыларга, шул исәптән югарыда телгә алынган Чыңгыз Айтматовка да тәэсире булган бу авторның бер генә юлы да татар теленә тәрҗемә ителмәгән. Дөнья хакында уйланулар белән тулы, йөрәк хисе ташып торган, гаделлек, кешелеклелек җырчысы, Испания кырларында, Франция күгендә нәләт суккан фашизмга каршы көрәшеп яшәгән Экзюпери иҗаты безнең укучылар күңелендә бик җылы, бик кадерле урын алыр иде. Миңа калса, егерменче

гасыр әдәбиятын Хемингуэй, Экзюперилар иҗатыннан башка аңлау да, аның тирәнлегенә төшенү дә мөмкин түгел. Без русның, илебездәге башка халык әдәбиятларының, дөнья әдәбиятының иң күренекле вәкилләрен үз телебезгә тәрҗемә итәргә, ул әдәбиятларны белергә, өйрәнергә, укучыбызны өйрәтергә һәм татар әдәбияты үсеше күренешләрен әнә шул дөньякүләм гомуми хәрәкәткә кушарга тиешбез.

Инде сүзнең иң аянычлы урынына җиттек. Ул да булса – татар язучыларының әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү мәсьәләсе. Рус телендә китап чыгару – дөньякүләм әдәбиятка керткән өлешебез ул. Әйтергә кирәк, без үз әдәбиятыбызның җимешләре белән хуҗаларча эш итәргә өйрәнмәдек әле. Муса Җәлил турында әйтмим, ул үзенең зурлыгы, бөеклеге белән безнең ваемсызлыгыбызны сикереп үтте. Аның китаплары рус телендә булсын, башка телләрдә булсын, СССРда да, чит илләрдә дә басылып чыгып киләләр. Муса Җәлил интернациональ культурабызның бер байлыгына әверелде. Ул, фашизмга каршы көрәш үрнәге булып, уяулыкка, батырлыкка, дуслыкка өндәп, илләр буйлап йөри, үткен хисләре белән халыклар арасында дуслык җепләрен туктаусыз суза. Татар халкының намусын, немец фашизмына каршы көрәшкә керткән зур өлешен Муса Җәлил билгеле бер дәрәҗәдә гәүдәләндерә. Ләкин халыкның сугыштагы батырлыгын гына күрсәтү – әле бу аның бер ягын гына күрсәтү дигән сүз. Татарстан җире – бай, җиргә-суга мул ил, аның атаклы игенчеләрен, нефтьчеләрен, галимнәрен бөтен җирләрдә дә беләләр, дияр иде берәү булса. Күп вакыт без шулай сөйләп юанышабыз да. Хәлбуки бу алай түгел. Татарстан нефтьчеләре дә, игенчеләре дә, җире дә, табигате дә, халкы да, тарихы да әле күп өйрәнүне, тырышлыкны, дәртне, көчне сорый. Чын сәнгать материалы булып эшләнеп, оста рәссам кулыннан чыккан тормыш күренешләре генә мәңгелек түгелмени? Салтыков-Щедрин[1]: «Әдәбият туктаса, тормыш туктый», – дигән иде.

---

[1] Михаил Евграфович Салтыков-Щедрин (чын фамилиясе – Салтыков, әдәби псевдонимы Николай Щедрин) (1826–1889) – күренекле рус язучысы.

Безнең халыкның күп гасырлардан килә торган тарихы бар, көрәш юлы бар. Безнең әдәбиятыбыз да моннан мең ел элек башланган. Күп булмаса да, тарих аның җәүһәрләрен, матур үрнәкләрен саклап калган. Без – Казан татарлары – атаклы Идел болгарларының төп варислары. Бүгенге көнгә җиде миллионлы булып килеп җиткән халыкның интернациональ культурага кертерлек казанышлары бар. Без елданел яңа әсәрләр: повестьлар, романнар, пьесалар иҗат итәбез. Әмма без шул казанышларыбызны чынлап торып эшкә җигә белмибез, уртак итә белмибез. Нигә инде яшереп торырга: үзебезнең бөек Тукаебызны да чынлап торып дөнья әдәбиятына чыгара алганыбыз юк ич әле!

Шагыйрь Шәүкәт Галиев сөйләшүләрнең берсендә, ачынып, болай дигән иде: «Тәрҗемәне мин шулай күз алдына китерәм. Кырдан, даладан бер кош тотып алалар да, эченбавырын йолкып чыгарып, корсагына мамык тутыралар, тегәләр, пыяла күз куялар, аннары музей киштәсенә урнаштыралар. Менә, янәсе, карагыз... аю шул була, төлке шул, кыр үрдәге шул... Тыштан караганда, чыннан да – аю, төлке, тик эч-бавыры урынында – мамык, күз урынында – пыяла. Тәрҗемә дә шулайрак. Ул да, түгел дә...» Шактый тапкыр һәм усал чагыштыру бу. Әгәр тәрҗемәне очраклы кешеләр эшлиләр икән, әгәр тәрҗемә алар өчен очраклы кәсеп, яшәү чыганагы гына икән, безнең яраткан әсәрләребез башка телләргә мамык йөрәкле, пыяла күзле булып барып ирешәчәк.

Дөрес, безнең Язучылар союзы тәрҗемәчеләр белән даими элемтәдә тора, аларны вакыт-вакыт җыеп ала, секцияләр эшли, җитди сөйләшүләр, бәхәсләр булып ала. Әмма татар теленнән тәрҗемә белән бүгенге көнгә кадәр татар телен белмәүчеләр шөгыльләнәләр. Алар арасында зур хөрмәткә лаек кешеләр булса да, тел белмәү аларга нык комачаулый.

Моннан берничә ел элек СССР Язучылар союзы, мондый хаксызлыкка чик куярга теләп, Мәскәүдә Әдәбият институты каршысында татарчадан русчага тәрҗемә итүчеләр әзерләү буенча махсус группа ачты. Биш-алты иптәш, институт бинасында тырышып-тырышып укып, белгеч булып чыктылар. Кызганычка каршы, белгечләрнең берсе дә Казанда эшләми. Берсе – Мәскәүдә, икенчесе – Уфада, Горькийда. Ул студент-

лар диплом яклаганда, мин дә чыгыш ясаган идем. Югары махсус белем алган тәрҗемәчеләрне «татар әдәбиятында тарихи шәхесләр болар, безнең өчен хәзерге көндә иң кирәкле кешеләр» дип атаган идем. Ләкин безнең ваемсызлык монда да үз тамгасын салды. Еллар буе «юк, юк» дип зар елаган, көткән белгечләребезне файдалана алмадык. Аларга үсәргә җирлек тудырмадык, ярдәм итмәдек. Нәтиҗәдә татарчадан туры русчага тәрҗемә итүчеләр саны искиткеч аз, сыңар кул бармагы белән дә санарлык. Безнең даими эшләп килә торган зур-зур язучыларыбызның да тыгыз бәйләнештә торган тәрҗемәчеләре юк.

Без Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Фатих Хөсни кебек өлкән язучыларыбызның иҗаты белән дә башка милләт укучыларын эзлекле рәвештә таныштырып бара алмыйбыз. Тәнкыйтьчеләребез дә гаҗәп дәрәҗәдә оялчанлык һәм тыйнаклык күрсәтәләр. Юбилей даталары белән басылган вак-төяк мәкаләләрне санамаганда, үзәк матбугатта татар әдәбияты, татар культурасы мәсьәләләренә кагылышлы материаллар күренми диярлек. Андый очраклы, буш мактау мәкаләләре исә татар әдәбияты кебек зур бер әдәбиятны үз эчләренә ала алмыйлар.

Мәсьәләнең ифрат мөһим тагын бер ягы бар. Безнең зур әдәбият мәйданына чыгуыбыз, киң катлау укучы массалар арасында таралуыбыз үз арабызда иҗат активлыгы, җитдилек, тормышка төплерәк үтеп керүне таләп итәр иде. Без үз әсәрләребезне Казан үлчәве белән дә, дөнья үлчәве белән дә чамалый башласак, бер дә зарар булмас иде! Ни әйтсәң дә, «дөнья стандартлары» дигән мәгънә монда да чит булмас иде!

Халыклар дуслыгы әдәбиятлар дуслыгы аша чагылыш табарга тиеш. Әдәбият эшлеклеләре, һәркайсы үз халкының тулы хокуклы вәкиле булып, шушы туганлыкны ныгытырга, халыкларның күңелләрен баету җәһәтендә туктаусыз эзләнергә тиешләр. Әдәби әсәрләрне телдән-телгә тәрҗемә итү – теге яки бу халыкның культурасын үстерү, рухын баету дигән сүз ул. Шуның өчен без үз халкыбызның күңел байлыгын, аның якты эзле тарихын, кунакчыллыгын, эш сөюен тугандаш халыкларга җиткерергә омтылырга тиешбез. Моның бердәнбер юлы – югары художестволы, сәнгатьчә эшләнгән,

талантлы әсәрләр иҗат итү. Һәм шул әсәрләрне үзебезнең уртак байлыгыбыз итәргә омтылу.

Рус җирендә без әсәрле, эзле без,
Тарихында бер дә тапсыз көзге без[1],–

дип язды безнең бөек Тукаебыз. Менә шушы якты эзнең үткәнен дә, киләчәген дә, хәзергесен дә әсәрләрдә беркетеп калу, яңадан-яңа әсәрләр иҗат итү – безнең намус бурычыбыз.

«Үги ана яфраклары»[2] хикәясе буенча радиоспектакль эшләгәндә, артист Әхтәм Зарипов[3] минем янга килде дә: «Хикәядәге Галимҗан шофёр нинди көйгә сызгырып бара?» – дип сорады. Минем җавабым әзер иде: «Григ музыкасын сызгыра»,– дидем.

Гади авыл шофёры... Ләкин күккә һәм җиргә карап төрле уйлар уйлана ала торган, мәхәббәтнең изгелеген, олылыгын бөтен җаны-тәне белән аңлаган, тәрбияле, нечкә күңелле һәм горур кеше. Ул матурлыкны кабул итә белә, күңеле гүзәллеккә омтыла, дөнья әдәбиятын – Экзюпериларны, Хемингуэйларны укый, төньякның бөек сихерчесе Григ музыкасын сөя, әмма бөтен барлыгы, бөтен яшәеше белән шушы җирдә, үзебезнең җирдә тора торган, яңа рухлы, Җир дип атала торган планета кешесе...

Мин Галимҗанны шундый дип беләм. Үзебезнең ил юлларында шундый егетләрне мин шактый очраттым... Бер Галимҗан гынамы?!

«Качак»[4] хикәясендәге Тәнзилә дә, «Дүртәү»дәге малайлар да, «Тәрәзәләр»дәге[5] нәни Һади да, «Берәү» повестендагы ике Сания дә, Исхак үзе дә – шушы Җир уллары. Мин үз илемнең кешеләрен илемне сөйгән кебек үк яратам. Алар

---

[1] Тукай Г. «Олугъ юбилей мөнәсәбәте илә халык өмидләре» // Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда.– Академик басма. 2 т.: шигъри әсәрләр (1909–1913).– Казан: Татар. кит. нәшр., 2011.– 384 б.

[2] А. Гыйләҗевнең 1961–1964 елларда язылган хикәясе.

[3] Әхтәм Исмәгъҗан улы Зарипов (1935) – актёр, режиссёр, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1979).

[4] А. Гыйләҗевнең 1958 елда язган хикәясе.

[5] А. Гыйләҗевнең 1960 елда язган хикәясе.

белән бергә яшәргә омтылам, кайгыларын уртак итәм, шатлыкларын бүлешәм.

1968 елда миңа кырык яшь тула. Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында туып, Зәй районының Югары Баграж авылында үскән малай... урта мәктәп... район комсомол оешмасында инструктор... сугыштан соңгы еллар. Мин, кулыма нәни сумка тотып, районның бер башыннан икенче очына җәяүләп чабам... Аннары – Казан, аннары – Казахстан, кирпеч заводлары, таш карьеры, төзелешләр, шахталар. Мин – ташчы, бетончы, буяучы, кочегар.

Мин, кайларда, нинди юлларда гына йөрсәм дә, һәрвакыт яхшы кешеләрне очраттым. Күңелемә тегенди яки мондый тирән эз калдырган, мине баеткан кешеләрне минем гомергә онытасым юк. Төрле хезмәт, төрле милләт кешеләре бар алар арасында. Минем язучылык бурычым – менә шуларны әдәбиятта мәңгеләштерү!

*1967, июнь*

## Драматургия, театр һәм тамашачы...[1]

### 1

КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карары безнең йөрәкләргә сары май булып ятты.

Бу һич арттырусыз шулай.

Тәнкыйть турында сүз бик вакытлы кузгалды.

Бер урындарак таптанган, сугышчан характерын югалта төшкән әдәби тәнкыйтьнең иң әүвәл үзен кузгатып җибә-

---

[1] А. Гыйләҗев 1972 елның маенда «Казан утлары» журналына тәкъдим итә. Кулъязмада Г. Ахуновның каләм белән язган искәрмәләре бар: «Бу әле мәкалә булып җитә алмаган. 1) Анализ юк. 2) Такт җитми – талашу тоны нык сизелә. Мөмкин кадәр сабыр, тыныч тонда сөйләп биргән чакта, шәхесләрне мыскылламаганда, кирәкле, җитди, сугышчан мәкалә булачак. Г. А.». Шулай ук Р. Мостафинның да каләм белән язган искәрмәләрен укырга мөмкин: «Мин бу мәкаләне фикер алышу тәртибендә бастыру ягында. Һәр кеше үзенчә фикер йөртергә хаклы. Бергәләшеп аңлашырбыз. Рафаэль Мостафин». 2015 елда «Сайланма әсәрләр» китабына кертелә (4 т., 352–374 б.).

рергә кирәк иде. Чөнки чын тәнкыйть – әдәбиятны оештыручы, аны әйдәп баручы. Чын тәнкыйть – әдәбиятның табибы, җилгәргече. Ул сортлы орлыкларны аерып алып сала, кибәген, чүп-чарын туздырып очырта.

КПСС Үзәк Комитетының карарында «тәнкыйтьнең торышы художество культурасының коммунистик төзелештә үсә барган роле белән билгеләнә торган таләпләргә әлегә тулы җавап бирми» дип күрсәтелә.

Бик дөрес бәяләмә бу!

Гомумән, әдәби тәнкыйтьнең торышы безне канәгатьләндерми икән, театр тәнкыйте өлкәсендә безнең хәлләр тагын да мөшкелрәк. Узган елгы әдәби ел йомгакларына багышланган, киң җәмәгатьчелек катнашында уздырылган, әдәби тормышыбызда мәгълүм дәрәҗәдә яңалык дип бәяләнгән утырышны гына хәтергә төшерик. Утырышта ясалган докладлар арасында иң йомшагы, иң фикерсезе Бәян иптәш Гыйззәтнең[1] драматургиягә багышланган чыгышы булды. Бу чыгыш, гадәттә, театр тәнкыйте өлкәсендә эшләүчеләрнең барлык йомшак якларын үзенә туплавы белән үрнәк булырлык дәрәҗәдә йомшак иде. Күп еллардан бирле театр тормышына актив катнашып килә торган фәннәр кандидатыннан, театр белгечләренә җитәкчелек итәргә куелган сектор җитәкчесеннән без күбрәк тә, төплерәк тә анализ көтәргә хаклы идек. Ә Баян иптәш һаман «бер җырны җырлады»: драматургиябездә, театр тормышында бара торган нигезле һәм бәрәкәтле үзгәрешләргә тирәнтен һәм объектив анализ ясый алмыйча, һәрвакыттагыча гади санап чыгу, бармак төртеп билгеләп бару белән канәгатьләнде. Сүз арасында гына кайберәүләрнең аркасыннан кагып куйды, кайберәүләргә аз-маз гына кара буяу сөртте.

Сүз сөйләргә алынганда мондый ансат бухгалтерия, мондый табельчелек белән шөгыльләнү кемгә кирәк икән дә, кемгә файдасы тия икән?! Баян иптәшнең чыгышы залдагыларда фикер, бәхәс уята алмады, драматургия турында сөйләшенергә тиешле сүзләр, гадәттәгечә, тел төбендә калдылар...

[1] Бәян Гыйззәт (Фәтхелбәян Нурлыгаян улы Гыйззәтуллин, 1918–1991), әдәбият галиме, театр сәнгате белгече, тәнкыйтьче. ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1989).

Әдәбият — берөзлексез хәрәкәттәге катлаулы процес икән, ул гомум санап чыгуларга берчакта да мохтаҗ түгел, иҗат кешеләрен, ишегалдындагы әрдәнә сыман, «берәүикәү, тагын бишәү, менә булды уналты!» дип теркәп-теркәп тезеп куярга ярамый.

Драматургия — башка жанрлар белән чагыштырганда аерата үзенчәлекле жанр, пьеса яза белү өчен талант өстенә махсус белем дә, профессиональ әзерлек тә, театр эшенә чын күңелдән бирелгәнлек тә кирәк. Монда инде Шәриф Хөсәенов, Туфан Миңнуллин, Хәй Вахит, Юныс Әминев кебек күренекле драматурглар тырышлыгы белән туган театр хәрәкәтенә анализ ясаганда, югарыда саналган иптәшләр янына Шамил Шаһгали[1], Галимҗан Сәгыйдуллин[2], Таһир Закиров[3], Рәисә Ишморатова[4] кебек үзешчәннәрне дә бер дәрәҗәгә кую, аларны бер чыбыркы белән куып йөртү, ким дигәндә, үз эшеңә җитди карамау, әдәби процессны бик томанлы гына күз алдына китерү һәм шул процессның авангардын билгели алмыйча азапланып маташу әдәби хәрәкәтебезгә зыян ясау итеп бәяләнергә тиеш.

Драматургиянең үсеш чыганакларын үз вакытында күрә алмау, яхшы белән яманга тиешле чын бәһане куя алмау, бер яктан, драматургларның иҗатларын тоткарлап торса, икенче яктан, тамашачыны бик күп буталышларга илтте, аны саташтырды.

Байтак еллар драматургияне, драматургларны «артта калалар, башка жанрлар белән чагыштырганда койрыкта сөйрәләләр» дип сөйләп килделәр. Ләкин ни өчен һәм ничек артта калуларына тиешле, файдалы анализ ясалмады. Драматургия артта кала, дип сөйләнәбез икән, бу — барыннан

---

[1] Шамил Шаһгали улы Миңлегалиев (1920–1987) — драматург.

[2] Галимҗан Сәгыйдуллин (1925–1971) — җырлар авторы.

[3] Таһир Закиров — үзешчән драматург. К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында — «Урман егете» (1964), «Яучылар» (1966), Минзәлә татар дәүләт драма театрында «Күрәселәрең бар булса» (1990) пьесалары сәхнәләштерелә.

[4] Рәисә Гыйниятулла кызы Ишморатова (Чебдарова, 1917–1997) — язучы, драматург. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1987).

да элек әдәби тәнкыйтебезнең дәрәҗәсе түбән булудан да килә. Димәк, безнең чынбарлык өчен бик кирәк моментларны тәнкыйть драматургиядә үз вакытында күреп ала алмаган. Димәк, тәнкыйть безнең эшебезгә комачаулаучы фактларны яралгысында ук фаш итә белмәгән. Яхшы белән яман бер үк дәрәҗәдәге хокуклар белән файдаланып, иркенләп яшәгәндә, әдәби хәрәкәттә һәрвакытта да халтурага, әрсезлеккә, һөнәрчелеккә урын кала.

Соңгы елларда газета-журнал битләрендә басылган байтак мәкаләләр, җыелыш-утырышларда сөйләнгән сүзләр драматургияне җанлы бер процесс итеп күз алдына бастыра алмадылар, шуның нәтиҗәсендә укучы мондый мәкаләләрне салкын, битараф каршылады. «Социалистик Татарстан» газетасы драматургиянең бүгенге торышы турында бер-ике тапкыр диспут башлап җибәрсә дә, бу диспутлар яңгырлы көндә көйрәтелгән учактагы чи чыбык кебек чожлап сүнеп онытылдылар.

Ниһаять, соңгы берничә ел эчендә драматургияне тоташ сүгүләр берникадәр кимеде, мактап ук бетермәсәләр дә, театр эшчәнлеге турында, драматургларның хезмәте турында ордым-бәрдем сөйләшүләр күзгә күренеп азайды.

Ни үзгәрде? Ни булды?

Бу турыда тирәнтен уйланырга кирәк. Булган уңышларыбызның серен ачып, аны уртак итәргә, беркетергә, уңышсызлыкларга каршы көрәш коралы итәргә кирәк. Башта ук әйтеп куйыйк: бүгенге көн татар драматургиясенең үсешен танымаска теләүче иптәшләр дә байтак. Мәсәлән, 1971 елның көзендә драматургия мәсьәләләренә багышлап Әлмәттә үткәрелгән республика киңәшмәсендә Мирсәй Әмир иптәш: «Драматургия үсә» дип сөйләргә иртәрәк әле, татар драматургларының бер генә әсәрен дә бөтенсоюз аренасына чыгара алганыбыз юк»,– дип раслап чыкты.

Драматургиянең үсеш казанышларын билгеләгәндә бөтенсоюз аренасына чыгу-чыкмау мәсьәләсе мөһим урынны тотса да, ул бердәнбер һәм иң төп критерий, үлчәү түгел әле. Бөтенсоюз аренасына күтәрелеп, байтак театрларда шаулап-гөрләп барган әсәрләрнең безнең пьесалардан күп түбән дәрәҗәдә торганнарын да беләбез. Соңгы сезонда иле-

бездә иң күп куелган пьесаларның берсе — «Берзаман Яңа ел төнендә»[1] исемле әсәр — безнең тамашачыларга Качалов театры сәхнәсе аша таныш. Бу пьеса үзенең зәвыксызлыгы, фикерсезлеге белән үзәк матбугатта хаклы рәвештә кире бәяләнде. Кайчагында шундый хәлләр дә була, җиңел кулдан гына тасланган сәхнә әсәрләре популярлашып, танылып китәләр.

Гомумән, теге яки бу әсәрнең сәхнә уңышын яки уңышсызлыгын бәяләгәндә, мөмкин булган бөтен критерийлардан чыгып эш итәргә кирәк. Күп кенә очракларда безнең иптәшләр тамашачының спектакльгә йөрү-йөрмәвен, сәхнә әсәрен бәяләгәндә, төп критерий итеп алалар. Тамашачы карыймы? Карый! Билетлар сатыламы? Сатыла! Димәк, «барысы да ал да гөл» дип әйтерлек, әсәр шома гына бара.

Моннан сигез-ун ел элек, аннан бераз соңрак та, безнең театрларны шактый нык тиргиләр иде, репертуар бертөрлелегендә гаеплиләр иде, иҗат оешмаларыбыз түбән зәвыклы әсәрләр белән мавыга, дип тә өстиләр иде. Гәрчә ул елларда да тамаша залларыбыз буш калмады. Татар драма театрлары һәр елны диярлек рентабельле булып килделәр. Әгәр сәхнә уңышын бары тик касса аша гына бәяли башласак, безнең ул еллардагы эшчәнлегебез гел мактауга гына лаек булыр иде. Хәлбуки без үз эшчәнлегебездән нигезле рәвештә канәгатьсезлек тоеп, борчылып яшәдек. (Ә драматургиянең уңышы яки уңышсызлыгы бары тик театр эшчәнлегендә күренә дә!) Тамашачының йөрү-йөрмәве мөһим критерий булса да, төп һәм бердәнбер критерий була алмый.

Безнең театрларны бер җирдә дә күтәреп мактамадылар, күтәргән проблемаларыбызныңваклыгы аркасында, режиссёрларыбызның бертөрлелеге аркасында, сәхнә персонажларының вак булуы сәбәпле, без һаман уртакул театр булып саналып килдек.

Соңгы өч-дүрт ел эчендә хәл кискен үзгәрде. Театрларыбызның дәрәҗәсе, бигрәк тә Ленин орденлы Академия театрыбызның абруе нык күтәрелде. 1970–1971 елларда Мәскәү,

[1] Э. Брагинский һәм Э. Рязановның 1969 елда язылган «С лёгким паром, или Однажды в новогоднюю ночь...» пьесасы турында сүз бара.

Уфа шәһәрләрендә булып узган гастрольләр театрның гомуми культурасы үсүен, аның иҗат коллективы буларак бөтенлеген, кызыклылыгын, үзенчәлекле милли коллектив булып ялтырап китүен, диапазоны киңлеген расладылар. Безнең театрлар белән сәнгать белгечләре, үзәк матбугат вәкилләре якыннан кызыксына башладылар.

Моңа сәбәп нәрсә булды?

Соңгы өч-дүрт елда нәрсә үзгәрде?

Драматургиянең үсешен, дәрәҗәсен нинди фактлар билгели? Без нинди төп факторлардан чыгып драматургиянең эшчәнлеген бәялибез?

Бүгенге драматургиянең чын йөзе – аның сугышчан характерда булуында. Бу – бер. Дөньякүләм кара-каршы ике идеология бәрелешкәндә, Җир йөзендә өзлексез дәвам итә торган көрәш, кешелекнең якты идеаллары өчен канлы сугышлар, бүгенгебез һәм киләчәгебез бездән ачык фикерле, чынбарлыкны дөрес тасвир итә торган, чорыбыз һәм бүгенге көн кешеләренең аң, белем югарылыгында иҗат ителгән югары художестволы әсәрләр таләп итәләр. Монда бернинди икеләнү булырга мөмкин түгел!..

«Чынбарлык» сүзен мин монда очраклы гына кулланмадым, бүгенге көн драматургиясенең үсешен билгеләүче икенче мөһим шарт, дияр идем мин аны.

Югары идеалларга хезмәт итүче, чын гуманизм рухы белән сугарылган әсәрләр генә режиссёрларны, рәссамнарны, актёрларны – кыскасы, театрның бөтен звеноларын кузгата ала, аларда иҗади яну уята, бары тик шундый әсәрләр генә киләчәк кешесен, һәр яктан камил булган коммунизм кешесен тәрбияли алалар. Тормыш агышына актив катнаша торган көчле рухлы, коммунистик һәм гуманистик идеалларга тугры геройлар, сугышчан характерлы актив образлар гына тамашачы күңеленә тәэсир ясый, аның күңеленә үтеп керә һәм гомерлеккә урнашып кала.

Сугышчан характерда булуны кайбер иптәшләр иң туры һәм аның бердәнбер мәгънәсендә генә кабул итәләр, шуның белән аның нигез фикерен, асыл мәгънәсен тарайталар. Әсәрнең темасына гына игътибарны юнәлтеп, кайбер очракларда сугышчанлык мәгънәсенә зарар китерәләр. Су-

гышчанлык ул – югары художестволылык, сәнгатьнең югары таләпләренә җавап бирә алу сәләте, ул – талантлы кул, кайнар йөрәк белән тудырылган әсәрләргә генә хас сыйфат. Сугышчанлык ул – чынбарлыкка күңел күзе белән карый белү, тау-тау өелеп торган тормыш фактларыннан бары тик берне – иң кирәклене, иң мөһимне сайлап ала белү. Сугышчанлык ул – намус сафлыгы, эчкерсезлек, пакьлек, чынлык.

Югыйсә бериш авторлар, үзләренең талант, әзерлек дәрәҗәләрен чамалап та тормыйча, теләсә нинди темага язарга тотыналар. Әлбәттә, алар еш кына көн өчен әһәмиятле яки «модный» темаларны сайлап алалар.

Әгерҗедән Рәшит Юнысов[1] «Туганнарга ышанмагыз» дигән комедия язды. Билгеле инде, әсәр «КамАЗ» төзелешенә багышланган. (Сүз арасында гына әйтеп үтик, узган елның декабрь аенда гына Татар академия театрына 25 пьеса керде, шуларның байтагысы «КамАЗга» багышланган!) Кирәкле темамы? Бик кирәкле! Ләкин автор яңа төзелешкә хас характерлар да, ситуацияләр дә таба алмаган. Гомумән, әсәрнең нигезен тәшкил иткән ситуация – ялган, ышандыру көче булмаган ситуация. Автор, Чаллыдагы гигант төзелешкә ышыкланып, чиле-пешле әсәрен сәхнәгә үткәрмәкче булган.

Тема белән сәүдә итәргә маташучылар бер ул гына түгел! Икенче бер автор, Рамазан Байтимеров[2], тарихи темага тотына һәм «Мәңгелек яшьлек» исемле пьеса яза. Октябрьнең 50 еллыгына багышланган бу «шедевр» кемнәр кулында гына булмады инде! Еллар узды, пьесаның багышлавы үзгәрә торды, хәзер ул «Совет дәүләте төзелүнең 50 еллыгына» багышлана. Автор кулъязмасын әле Әлмәт театрына илтә, әле Минзәлә шәһәренә күчерә. Әлмәт театрына илткәндә, Гражданнар сугышы чоры эпизодларын Әлмәт-Бөгелмә тирәләренә «күчерә», Минзәлә театрына тапшырганда, сугыш хәрәкәтләре «стратегик тизлек белән» Минзәлә шәһәренә

[1] Рәшит Юныс улы Юнысов (1930–2011) – язучы.

[2] Рамазан Муллагали улы Байтимеров (1923–1989) – шагыйрь, язучы, драматург. Р. Байтимеровның күп кенә шигырьләренә Р. Яхин, С. Садыйкова, Ә. Бакиров, Б. Мөлеков кебек күренекле композиторлар көй язган. Аның «Туган ягым» шигыренә Р. Яхин иҗат иткән җыр Татарстан гимнының нигезен тәшкил итә.

күчәләр. Әдәби принципсызлыкның, гражданин буларак җавапсызлыкның югары үрнәге булган шушы чеп-чи халтура чак кына Минзәлә театрына үрләми калды! Җәмәгатьчелек һәм Культура министрлыгының катнашы белән генә пьесаның юлы киселде.

Бер иптәш, Шамил Шаһгали, Вьетнам турында пьеса язарга алынган. Иптәшнең Вьетнамда булганы юк, ул халыкның милли үзенчәлекләрен бик чамалы гына белә, сугыш картиналарын бик томанлы гына күз алдына китерә. Мондый әзерлексез күңелдә туган әсәрнең халкыбыз өчен нинди файдасы булуы мөмкин?

Бу иптәшләрнең күңелләрендә ташып торган фикер дә юк, кулларында материал да бик аз, ләкин алар шундый олы, изге темаларга бик теләп ябышалар, тема, бу очракта, аларга сәүдә юлы гына.

Соңгы елларда театрларыбыз тамашачыны Хәй Вахит пьесалары аша тәрбияләделәр. Бу – бүгенге көнебезнең актуаль мәсьәләләрен аның аркылы чишәләр, дигән сүз.

Сәнгатьнең югары таләпләреннән чыгып эш иткән очракларда, Хәй Вахит иҗаты беренче көннәреннән үк җитди тәнкыйть сүзләренә очрады. Ләкин күп очракларда Хәй Вахитны мактадылар. Автор тәнкыйть сүзләренә колак салмады, үзе сайлаган сукмактан тайпылмады, баш бирмәде, һаман бер темпта, сыналган алым белән яза торды.

Бериш кешеләр «Хәй Вахит тамашачының активлыгын көчәйтте, театр эшчәнлегенә яңалык кертте» дип расларга ярата лар һәм театрлардагы уңышларны бары тик бер кеше иҗаты белән генә аңлатырга телиләр. Эш нәрсәдә иде соң? Хәй Вахит спектакльләренә тамашачының шулай актив йөрүенең хикмәте нәрсәдә?

Беренчедән, безнең театрларга Кәрим Тинчуринның, Салих Сәйдәшевнең яңадан кайтуы халкыбызда аерым бер энтузиазм тудырса, театрлар, аерым алганда, Татар академия театры, безнең милли мирасыбызга, үткәндәге драматургларның иҗатларына йөз белән борылып, заман һәм чор таләп иткән югарылыктагы спектакльләр иҗат итте. К. Тинчурин, Т. Гыйззәт, Г. Камалларның үз вакытында әллә ни дан казанмаган әсәрләре дә бүгенге көн сәхнәсеннән яңа аһәң белән,

бүгенге көн идеалларына хезмәт итә торган аһәң белән яңгырадылар («Американ»[1], «Сүнгән йолдызлар»[2] һ.б.)

Драматургның кайсы вакытта әдәбиятка килеп керүе дә шактый әһәмиятле урын тота. Әгәр ул үз вакытын белеп, үз кирәген сизенеп пәйда була икән, бу – аның бәхете. Конфликтсызлык теориясе тудырган төссез, соры пьесалардан арынып килгән бервакытта, салмак хәрәкәтле «псевдопроизводственный» пьесалардан сару кайнаган чорда, елкылдап-ялтырап, Хәй Вахит әсәрләре килеп чыкты. Салават күпере төсле җемелдәгән комедияләр, җиңел сөякле водевильләр бер катлау тамашачының, бигрәк тә авыл тамашачысының, күңеленә хуш килде, аны исертте, кәефләндерде. Тамашачы Хәй Вахит пьесаларында онытылып ял итте.

Автор театрга үз вакытын тоеп, үз кирәген белеп килде. Һәм үзенең кайсы юнәлештә кирәклеген бик тиз төшенеп алды, аңлап алгач, тезгенне кулыннан ычкындырмады.

Шуның өстенә Хәй Вахит – махсус сәнгать белеме алган, профессиональ осталыкка ия булган автор. Ул сәхнә кануннарын, аның «йомшак» һәм «каты» якларын бик яхшы үзләштерде, юктан барны да ясап куя алды, укмаштырды, таслады.

Тагын бер мөһим аспектны әйтми калдырырга ярамый. Хәй Вахит үзенең эшчәнлегендә ялгыз түгел иде. Бер төркем яшь актёрлар, режиссёрлар аның әсәрләрендә күренеп, үсеп калдылар. Рәфкать Бикчәнтәев[3], аның әсәрләрен куеп, режиссёр булып танылды. Театрда драматургның әсәрләрен күңеле белән кабул итүче, аның фикердәше, көрәштәше булырлык режиссёрның эшләве – автор өчен бәхетле очраклардан берсе. Хәй Вахит белән Рәфкать Бикчәнтәев байтак еллар фикердәш, иҗади яктан дус булып яшәделәр. Р. Бикчәнтәев исә, үз чиратында, актёрлар арасыннан үзләренә фикердәшләр, дуслар туплады.

---

[1] К. Тинчуринның 1924 елда язылган комедиясе.

[2] К. Тинчуринның 1924 елда язылган драмасы.

[3] Рәфкать Әхмәтҗан улы Бикчәнтәев (1924–1975), актёр, режиссёр. ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1960).

Димәк, Хәй Вахит үз вакытында килеп чыкты. Үз режиссёрын, үз актёрларын, үз тамашачысын тапты. Бу – сирәк язучы өлешенә чыга торган бәхет иде.

Шулар өстенә Хәй Вахитның талантлы булуын да, эшлекле икәнлеген дә, гаҗәп дәрәҗәдә хәрәкәтчән булуын да, мобиль икәнлеген дә әйтеп узарга кирәк. Театр – катлаулы оешма, авторның берникадәр мобиль булуы да, театр юксынып торгандарак әсәр язып китерүе дә кайбер очракларда аның уңышын билгеләүче булып китә.

Тагын бер моментка тукталасы килә. Театрлар бер Хәй Вахит әсәрләре белән генә яшәмәделәр ич. Дөнья әдәбиятыннан, рус классикасыннан, тугандаш халыкларның иң әйбәт әсәрләрен сайлап алып, театрлар аларны да өзлексез уйнап килделәр. Башка авторларның пьесалары да дөнья күрә торды. Әмма безнең театрлар югары рангка һаман күтәрелә алмадылар.

Моннан бик мөһим, бик гыйбрәтле нәтиҗә ясап була: димәк, театрның чын йөзен, аның иҗат юлын дөнья әдәбияты үрнәкләре белән берлектә, шуларга тиң булырлык дәрәҗәдә иҗат ителгән милли әсәрләр генә билгели. Театр заманга хас үзенең төп приципларын бары тик милли әсәрләр югарылыгында гына чишә ала! Бу факт бәхәссез булса кирәк һәм хәзерге заман драматургларына нинди зур бурычлар йөкләнүен бик яхшы күз алдына китерергә ишарәләүче факт! Театр белән драматургия бер-берсенең үсеш дәрәҗәләрен тәэмин итеп, бер-берсенең үсеш югарылыгы мөмкинлек биргән хәлдә үрелеп үсә баралар. Бер театрның да үз драматургиясеннән аерылып китеп, беренчесенең алдарак барып, икенчесенең арттарак калу очрагы юк. Без бүген «Академия театры союз күләмендә дан казанды!» дибез икән, бу – безнең милли драматургиябезнең дәрәҗәсен дә күрсәтә. Мин бу очракта милли драматургиябезне бүгенге көн авторлары белән генә чикләп куюдан ерак торам. Театр барыннан да элек Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт, Нәкый Исәнбәтләргә бурычлы. Алар кичә дә, бүген дә, киләчәктә дә безнең театрыбызның үсешенә, режиссурабыз югарылыгына, актёрлык осталыгына тәэсир ясап торучы, аны билгеләүче тере күңелләр булып калачак.

Әйткәнебезчә, театрларның алга барышында классик драматургия үрнәкләре, тугандаш халыкларның иң яхшы әсәрләре гаять әһәмиятле рольне уйнасалар да, безнең чынбарлыгыбызны, бүгенгебезне актив чагылдырган милли пьесалар театр сәнгатендә хәлиткеч урынны тота. Бары тик хәзерге заман югарылыгындагы милли әсәрләр куя алган, заман проблемаларын милли пьесаларда, җирле материаллар белән чишәргә сәләтле театрлар гына бүгенге көннең югары таләпләренә җавап бирә алалар. Аерып-аерып алганда, дөнья классикасы да, рус совет әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре дә үзләре генә хәзерге заман тамашачысының зәвыгын канәгатьләндерә алмыйлар. Репертуарның төп өлешен, үзәк өлешен, хәзерге заман темасына багышланган, коммунистик төзелеш идеалларына тугрылыклы, талантлы кешеләр тарафыннан иҗат ителгән хәзерге заман спектакльләре алып торырга тиеш.

Хәй Вахит үзенең максатын тормышка ашырды, үзенең мактаулы эшен башкарды. Аның иҗат принциплары берьяклырак булып калды, театрлар аның әсәрдән әсәргә күчеп йөрүче, бер үк төстәге, исем-фамилияләре генә алмашынган геройларыннан ялыктылар, аның соңгы пьесалары театр коллективлары тарафыннан хаклы рәвештә кире кагылды.

Монда, бер караганда, искитәрлек әллә нәрсә юк та кебек. Фатих Хөсни әйтмешли, «кытаклаган саен алтын йомырка салып булмый». Әмма, пьесалары кабул ителмәгәч, Хәй Вахитның буран куптарып йөрүе, кемнәргәдер балалар төсле рәнҗүе, драмсекция эшеннән, театрларның худсоветы эшеннән бөтенләй баш тартып, иҗат оешмаларыннан читләшеп, кимсетелгән кеше кыяфәтендә йөрүе – аңлатып булмый торган ямьсез күренеш.

Инде безгә үпкәли икән, драматургларны күремсезлектә гаепли икән, театр сәнгатенең олы бер кешесе – Нәҗип Җиһановның сүзләренә колак салмый калмагандыр! Нәҗип Җиһанов «Социалистик Татарстан» газетасында болай дип язып чыкты: «Соңгы елларда Опера театрында татар операсына игътибар сизелерлек кимеде. Моны театр репертуарыннан да күреп була. Дөрес, яңа художество җитәкчеләре бу турыда уйланалар, ләкин әлегә бик акрын кыймылдыйлар. Иң бе-

ренче планга акча мәсьәләсе килеп баса. Шуңа күрә иҗади обстановка кимеп, репертуарда жанрлар буталчыклыгы күренә башлады. Сәхнәгә түбән зәвыклы яңа опера, яңа музыкаль комедия булмаган спектакльләр чыгарыла башлады. Мин Хәй Вахит либреттосына С. Садыйкова[1] һәм Р. Гобәйдуллинның[2] «Мәхәббәт җыры»[3] һәм быел әзерләнә торган «Кияүләр»[4] әсәрләрен күз алдында тотам («Чорыбыз сулышы чагылышы» исемле мәкалә.– 1971.– 28 ноябрь).

Без алдарак бу сүзләргә тагын бер тукталырбыз әле, хәзергә игътибарны Хәй Вахитка биргән бәягә генә юнәлтәбез. Мәкалә басылганда, «Кияүләр» чыкмаган иде әле. Спектакль куелды, бара, әмма җәмәгатьчелек тарафыннан каты гына тәнкыйтькә очрады. Әлеге дә баягы зәвыксызлык, күп кенә ситуацияләр ышандырмый, автор тарафыннан гына уйлап чыгарылганлыгы сизелеп тора... Бу жанр «җиңелләр» рәтеннән йөри. Тик бу аңа җиңел фикерләр төяргә мөмкин дигән сүз түгел әле. Спектакльдә ике кияүнең икесе дә лаякыл исерек, хәтта Барлас үзенең кәләше беләнме, әллә кәҗә янында йоклаганмы икәнлеген ачыклый алмый азаплана... Гомумән, либреттоның йомшак урыннары бик күп. Бу комедия коры уенга гына корылган. Халыкча әйтсәк, корыны бушка әйләндерү. «Социалистик Татарстан» газетасының 1972 ел, 2 апрель санында да бу мәсьәлә турында сүз кузгатыла.

Хәй Вахитның ситуацияләрне уйлап чыгарырга осталыгы кайвакытта җитди тәнкыйтьчеләрне дә ялгыштырып куя. Хәтта Рафаэль Мостафин да аның бу кимчелегенә күз йомарга әзер. «Әгәр Хәй Вахит сәхнә законнарын шәп белә, комедиячел ситуацияләр таба, тамашачыны киеренке хәлдә тота, үз артыннан ияртә ала икән, бу – начар сыйфатмыни?

[1] Сара Гариф кызы Садыйкова (1906–1986) – актриса, җырчы, композитор. ТАССРның атказанган артисткасы (1939), ТАССРның халык артисткасы (1977), РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1984), Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1990).

[2] Рәшит Гомәр улы Гобәйдуллин (1931–2000) – композитор.

[3] Р. Гобәйдуллинның 1971 елда С. Садыйкова белән берлектә иҗат ителгән музыкаль комедиясе.

[4] Р. Гобәйдуллинның 1972 елда С. Садыйкова белән берлектә иҗат ителгән музыкаль комедиясе.

Инде еш кына аның әсәрләренә тормышча тирәнлек, зур иҗтимагый мәсьәләләр күтәрү, безнең чынбарлыкның яңа, кызыклы якларын чагылдыру җитми икән, бусы – бөтенләй башка мәсьәлә», – дип язды ул[1].

Ни өчен башка мәсьәлә, хөрмәтле иптәш Мостафин?!

Әйе, нәкъ сез таләп иткән Хәй Вахит ситуацияләр кора белә. Әлбәттә, кияүнең кәҗә янында йоклап калуы бериш халык өчен кызыктыр да, аларның күңелләре кытыкланып, «киеренке кыяфәттә утыралардыр» да, әмма бүгенге драматургиянең максаты бары шул гынамы?!

Р. Мостафин – әдәбиятны тирәнтен аңлаучы иң төпле тәнкыйтьчебез. Бу мәкаләсендә ул, үзенә үзе каршы килеп, берьяклылыкны алгарак сөргән. Хәй Вахит үзенең талантын җитди, төпле һәм чын нәтиҗәле эшкә җигәргә тиеш. Ул тормышчан тирәнлеккә төшәргә, чынбарлыкка сугышчан күз белән карарга, зур иҗтимагый мәсьәләләр күтәрергә, XX съезддан соң башланган бәрәкәтле хәрәкәткә лаеклы хезмәт күрсәтергә, ялган иҗат принципларының колы булып калмаска тиеш.

Хәй Вахит – күренекле драматург, Г. Тукай бүләге лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Аның сүзе хәзер алтын бәһасенә йөрергә тиеш. Аның сүзенә театрлар колак салалар, яшь драматурглар ияреләр. Аның элеккеге иҗат принципларының берникадәр кризис кичерүе аның белән бергә иҗат иткән режиссёрларда да чагылды. Рәфкать Бикчәнтәевнең Академия театрын ташлап чыгарга мәҗбүр булуы, «башын кая куярга белмичә» каңгырып йөрүе дә безне бер тапкыр уйландырырга тиеш. Хәзерге көндә Республика күчмә театрында эшли башлаган Р. Бикчәнтәев, җиңел жанрда эш итеп канатланган кеше, коры уенга гына корылган әсәрләргә юл ачмасын. Аның да элеккеге хаталары кабатланмасын иде.

Хәй Вахитның драматургиясе, әйткәнебезчә, байтак ияреп баручылар тудырды. Таһир Закиров чиле-пешле әсәрләрен, гадәти уен ситуацияләренә генә корылган фикерсез байтак әсәрләрен сәхнәгә менгереп өлгерде. Үзешчән авторлар күп кенә чүпне тамашачы алдына чыгарып калдылар. Чаллы

[1] Казан утлары. – № 5. – 172 б.

халык театрында куелган «Чишмә җыры» (Мансур Кашапов[1] әсәре), Зеленодольск халык театрының «Уяну» пьесасы (Джон Гомәров[2] әсәре) әнә шундый чеп-чи халтура әсәрләре исемлегенә керәләр. Быел Мамадыш халык театры, Галимҗан Сәгыйдуллинның «Тормыш хөкеме» исемле зәвыксыз әсәрен Казанда күрсәтеп, җәмәгатьчелек тарафыннан кискен хөкем алып китте (режиссёры Ф. Фарсин[3]). Халтурачыларны, акрынлап булса да, тормыш үзе хөкем итә.

Хәй Вахит драматургиясе, авторның үзенчәлекле, уңай яклары булуга карамастан, безнең үткән көнебез. Без бу турыда, авыр булса да, тайчынмыйча әйтергә тиешбез. Авторның үзе өчен дә, аның иярченнәре өчен дә бу – ачык булырга тиеш. Тормышта һәрвакыт үзгәрешләр булган кебек, сәнгать тә бер урында гына таптанып тора алмый. Театрга яңа буын, яңа авторлар, яңа эшлекклеләр килде. Әгәр без шушы яңарышның үзәк моментларын тотып алып бәяли белмәсәк, үсешебезгә мәгълүм бер дәрәҗәдә зыян китерәчәкбез.

Тамашачы, театр, драматург – бу өч звеноның берсе генә артта калса да, сәнгать үсүеннән туктый. Болар – бер-берсенең үсешен тәэмин итеп, бер-берсен әйдәкләп, оештырып баручы, тыгыз контактта яшәргә тиешле звенолар. Режиссёрлар белән актёрлар – бер яктан, таләпчән, зәвыклы тамашачы икенче яктан шәхси, индивидуаль талантка ия булган язучыны чын киеренкелектә тотканда гына, ул тормышны төзүче буларак кайнап, көрәш мотивлары белән рухланып яшәгәндә генә, бүгенге көннең сәхнәсен бизәрлек әсәрләр тудыра ала.

Соңгы еллар театрларындагы үзгәрешләрне яңа режиссёрлар, яңа авторлар килү белән генә чикләү берьяклырак булыр иде. Яңа режиссёрлар, яңа авторлар тормыш тирәнлегенә аңлы рәвештә, максатчан үтеп керә башладылар. Менә нәрсә мөһим! Авторларның үзләрен, иҗат кешесе буларак, бер-бер-

[1] Мансур Кашафетдин улы Кашапов (1922–?) – драматург, халык театры режиссеры.

[2] Джон Хәбибрахман улы Гомәров – Яшел Үзән милли театрының беренче җитәкчесе.

[3] Фердинанд Юныс улы Фарсин (1930–2012) – актер, Татарстанның атказанган артисты.

сеннән ялгышусыз аерып була, алар тормышның олы яки кече вакыйгалары аша кешелекнең зур проблемаларын, чорыбызның катлаулы төеннәрен чишәргә тырышалар. Ниһаять, бүгенге көнгә татар драматургиясенә җитди-фәлсәфи уйлану, гомумиләштерү хас. Элегрәк мондый әсәрләр сирәк-сорак кына күренеп китәләр иде, театрлар аларга үгисетебрәк карыйлар иде, хәзер исә заманыбызның драматургиясен җилкәләрендә тотып торучы Ш. Хөсәенов, Т. Миңнуллин, Ю. Әминев, яшь драматург Диас Вәлиевләр инде нәкъ шул югарылыктан торып иҗат итәргә тырышалар. Театрларга, ниһаять, иҗади йөзләре, сәхнә алымнары төрле-төрле булса да, иҗат принциплары, сәнгатькә карашлары уртак булган драматурглар килде. Алар, чишмә булып, һәркайсы аерым таудан бәреп чыктылар да тиз агымлы, шау-гөрле елга тудырдылар. Менә бу авторларның әсәрләре дөнья, рус классиклары пьесалары белән берлектә, тугандаш халыкларның иң мактаулы үрнәкләре белән янәшә торып, алар белән бер югарылыкта, театрларыбызның кайберләренә сизелерлек үсеш, яхшы исем, дан китерделәр.

Ш. Хөсәенов, Т. Миңнуллин, Ю. Әминев, Д. Вәлиевләр өчен уртак сыйфат – аларның талант ияләре булуда. Талантлы булу өстенә алар тормыш күренешләренә, яшәешнең барлык сфераларында бара торган сыйнфый һәм иҗтимагый көрәш күренешләренә битараф кала алмый торган гражданнар, чын шәхесләр дә. Хәзерге драматургларда исә, ситуация кора белү осталыгы булу өстенә, заманча фикер, кискен көрәш элементлары ярылып ята. «Әни килде»[1], «Ир-егетләр»[2], «Намус хөкеме»[3], «Минем җинаятем»[4] пьесалары, сюжетлары белән тамашачыга актив рәвештә тәэсир итү белән бергә, куелган һәм чишелә торган фикер тирәнлекләре ягыннан аны актив уйланырга мәҗбүр итәләр, фәлсәфи чыгармалары, уртага салынган олы язмышлары аша күңелләрне озакка кузгаталар. Бу пьесаларда куелган кешелеклелек, үзара ярдәм, туганлык, сафлык, чисталык мәсьәләләре ха-

[1] Ш. Хөсәеновның 1968 елда язылган пьесасы.

[2] Т. Миңнуллинның 1971 елда язылган пьесасы.

[3] Д. Вәлиевнең 1971 елда язылган беренче пьесасы.

[4] Ю. Әминевнең 1968 елда язылган пьесасы.

лык арасында киң резонанс алды. «Әни килде» пьесасының кыска гына вакыт эчендә 200 мәртәбә уйналып, 200 аншлаг алуы – безнең тамашачының зәвыгы, сәнгатьне аңлавы үсүен раслый торган дәлилләрнең берсе. «Ир-егетләр» кебек үтә җитди, ярым публицистик, әмма уй-фикере белән безгә, безнең театрга бик кирәкле пьеса да өзлексез уйналып, куелып килә. «Намус хөкеме» пьесасы җитди уйлануларга, вакыт һәм чор турында, намус һәм намуссызлык турында төпле бәхәсләргә корылган. Бу спектакль дә Академия театрында лаеклы урын алды.

Моннан берничә ел элек «Смена»[1] журналында күренекле рус драматургы Афанасий Салынский[2] Туфан Миңнуллин турында болай дип язды: «Художникның җитлегүен таланты белән бергә гражданин булып өлгерүе дә раслый. Туфан Миңнуллин Татарстаннан безгә «Нигез ташлары» исемле пьесасын алып килде. Пьеса көрәшче дә, халыкның улы да була белгән автор тарафыннан каты һәм киң күңел белән язылган. Драматург материалының чынлыгына шикләнерлек урын юк: сюжетта Туфан Миңнуллинның үзенә һәм чордашларына таныш вакыйгалар турында сөйләнелә. Сугыштан батыр булып ата кайта, колхозны җитәкли, тормышның нигезен салучы һәм яңа заман коручы балаларын чын юлга чыгара. Туфан Миңнуллин – солдат улы, үзе дә солдат, ул үзенең үткер, ышанучан сүзе белән, хисе белән көрәшә. Безне гел алгы сызыкка чакыра».

«Бәхетле кияү», «Миләүшәнең туган көне», «Нигез ташлары», «Секретарьлар», «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Ат карагы», «Койрыклар», «Ир-егетләр» һәм, ниһаять, «Уйланыр чак» пьесаларын иҗат иткән Туфан турында моннан да ачыграк, килешлерәк итеп әйтеп булырмы?

Туфан Миңнуллин театрның көтеп алынган драматургы булды. Ул бәхетле иҗат чорын кичерә, аның әсәрләре елдан-елга төплерәк, гыйбрәтлерәк була баралар. Ул – белемле, уйланучан, нәтиҗәле фикер йөртергә сәләтле, үз тор-

---

[1] Мәскәүдә 1924 елдан нәшер ителүче әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси айлык журнал.

[2] Афанасий Дмитриевич Салынский (1920–1993) – рус совет драматургы. СССРның Дәүләт премиясе лауреаты (1984).

мыш принциплары булган, үз иҗат йөзе табылган автор. Ул үз сүзен үткәрер өчен пәрмә-пәр сугыша да ала, чөнки ул күтәргән мәсьәләләр өчен сугышырлык та була. Көрәшә белә, чөнки әсәрләрен кайнар кан белән яза, ялагайлыкны, пассивлыкны, битарафлыкны кичерми, гафу итми торган сугышчы. Тормыш күренешләренә явызланып карамый, төчеләнеп алга манмый, уңай һәм кире геройларына бердәй җитди күз белән карый, сөйгәндә, чын итеп сөя, сөймәгәндә, нәкъ кирәгенчә нәфрәтләнә ала. Бу юлы аны гел югарыга илтәчәк, иҗади кысырлыкны Туфан белмәячәк, киресенчә, аның иҗаты үсә, камилләшә генә барачак. Гражданин һәм солдат буларак ул һәрвакыт уйда, һәр көн хәрәкәттә. Тормыш аны үзе белән ияртеп алып бара, Туфан тормышның үзен әйдәкли, алар бергәләп үсәләр. Ул – тулы канлы шәхес, ул театрлар тормышына, сәнгать тормышына даими катнаша, театрлар эшчәнлеге өчен янып-көеп йөри. Аны яңа пьесалар укыганда да, премьераларда да, киңәшмәләрдә дә һәрвакыт күреп була. Үз фикерләрен ул еш кына матбугатта да чыгара, тулы канлы камил тормыш белән яши.

Күп режиссёрлар аның яңа әсәрләре белән янып яшиләр, аның белән иҗади бәйләнештә торырга тырышалар. Быелгы җәйге гастрольләрнең афишасына күз салсак, без Туфан Миңнуллинның бүгенге көндә мәдәни тормышыбызда нинди роль уйнавын ачык күрербез. Татар дәүләт академия театры аның «Ир-егетләр» һәм «Диләфрүзгә дүрт кияү» әсәрләрен гастрольләргә алып чыкты. Күчмә театр «Уйланыр чак» һәм «Секретарьлар»ны күрсәтә. Шул ук театр көчләре белән Юлиус Эдлисның[1] «Мәхәббәтем хакына» исемле пьесасы сәхнәләштерелде. Русчадан аны Туфан Миңнуллин тәрҗемә иткән. Әлмәт театрында – бер[2], Бөгелмә театрында[3] рус телендә бер пьесасы бара Туфанның... Кайбер кичләрдә татар

---

[1] Юлиус Филиппович Эдлис (1929–2009) – драматург, сценарист.

[2] 1944 елда колхоз-совхоз театры буларак ачыла, 1951 елдан драма театры, 1985 елга кадәр – күчмә театр.

[3] 1935 елда һәвәскәрләр түгәрәгеннән оешкан Бөгелмә рус драма театры.

һәм рус тамашачылары Туфанның алты спектаклен карыйлар.

Без бу авторның иҗаты туктаусыз югарыга үсүен, тагын да яктырак үрләр яулавын теләп калабыз.

Шәриф Хөсәенов пьесаларны аз яза. Ул – нибарысы күләмле дүрт пьесаның авторы. «Профессор кияве», «Чулпан», «Зөбәйдә – адәм баласы», «Әни килде» пьесалары – тамаша залларында җанланыш, зур бәхәсләр тудырган югары художестволы әсәрләр. Ш. Хөсәеновның да иҗат адымы, үзенең яраткан темасы, үзе генә күтәргән мәсьәләләре бар. Авторның идеалы – яхшылык, гаделлек, гуманизм. Аның төп дошманы – хәзерге заман мещаннары, мещанлык күренешләре. Тышкы яктан шома гына яшәүче респектабльле, ару гына урыннарда хезмәт итеп килүче кешеләрнең күгәргән, чери башлаган эчке дөньяларын ул көйдергеч фаш итә, үткен теле, тере җанлы кабатланмас образлары белән аяусыз камчылый. Ш. Хөсәенов пьесалары турында кискен тәнкыйть фикерләре дә булды, бигрәк тә «Әни килде» пьесасы турында бериш тәнкыйтьчеләр җилкә җыерып сөйләнгәләделәр. Мәскәү гастрольләре вакытында бу урынсыз көчәнүләргә чик куелды, пьеса һәм спектакль «Правда» газетасында уңай бәя алды, «Әни килде» рус теленә тәрҗемә ителде. Илебезнең байтак театрлары ул пьесаны сәхнәләренә менгереп өлгерделәр дә инде.

Театрларга байтактан хезмәт күрсәтеп килүче авторларыбыздан Юныс Әминевкә былтыр 50 яшь тулды. Бу искиткеч тыйнак, әмма тынгысыз җанлы кеше, хезмәт сөючән намуслы автор соңгы елларда байтак җитди пьесалар иҗат итте. «Гөлҗәннәтнең җәннәте», «Кеше күңеле», «Минем җинаятем» пьесалары бер-бер артлы сәхнәгә куелды. Ул күп еллардан бирле гади хезмәтне сөюче самими геройларына тугрылыклы булып килә, шулар турында яза.

Соңгырак язылган «Гөлҗәннәтнең җәннәте» һәм «Минем җинаятем» пьесаларына фәлсәфи тирәнлек, эчке зур мәгънә һәм югары гражданлык хисләре хас. Әлмәттә уздырылган киңәшмәдә «Минем җинаятем» спектакле каршылыклы фикерләр тудырды. Спектакльгә анализ ясарга керешмичә, пьеса турында бер-ике сүз әйтеп китәргә кирәк дип саныйм.

Пьеса, кайбер иптәшләр аңлаганча, яшь бер тракторчының шәһәргә укырга китеп, спорт ярышларында катнашып макталуына, нәтиҗәдә – бозылуына, ниһаять, хыянәтче һәм ялганчыга әверелүенә генә багышланмаган. Әгәр пьеса бары тик шул турыда гына булса, әсәр гадәти газета фельетоныннан еракка китмәгән булыр иде. Хикмәт шунда ки, Әминевнең фикере күп мәртәбәләр тирәнрәк, төплерәк, җитдирәк. Ул, бик борчылып, әнә шул җинаятьнең тамырына төшәргә, аны тудыручы сәбәпләрне ачыкларга тели. Чыннан да, ничек әле барыбызның да күз алдында гап-гади, тырыш бер тракторчыбыз, бәхетле гаилә корып җибәргән сөйкемле егет, җинаятьчегә әверелде?! Кем гаепле монда? Кайсыбыз?.. Юныс Әминев безнең күз алдыбызда шушы җинаятьне ихтыярсыз тудырган кешеләрне уздыра. Егетнең әнисе дә, хатыны да, каенатасы да, аны өф-өф итеп кенә йөрткән бригадир ханым да бердәй гаепле монда. Алар, яхшылык эшлибез дип, чеметем-чеметем генә егетне бозалар, үзгәртәләр, ниһаять, җинаять юлына этәрәләр. Сүз егетнең җинаяте турында түгел, ә безнең – ваемсызларның һәм битарафларның, яхшы белән яманны аера алмаганнарның кылган эшләре турында бара. Бу зур фикерне Юныс Әминев тиешле югарылыгында чишкән. Тракторчы егетне уйнаучы актёрның рольне беркадәр «кәнфит кәгазенә төреп бирүе» генә автор фикерен бераз боза төшкән...

Ю. Әминевкә кыюлык җитеп бетми. Театр җитәкчеләре белән сөйләшкәндә дә, үз сүзен сүз иткәндә дә, ул артык юаш. Моннан берничә ел элек ул «Үлемнең үлеме» исемле пьеса язган иде. Бу пьеса аның иҗаты өчен яңалык иде. Әсәрнең нигезендә безнең социалистик җәмгыятьтә, халыклар дуслыгы чәчәк аткан җәмгыятьтә, «кеше кешегә дус һәм туган» дигән мораль принцип тормышка ашырылганда, Үлем үзе үлемгә дучар була. Менә нинди социаль шартларга куелган ул! Бу тирән фикерле пьеса да үзенең чын хуҗаларын көтә.

Юныс Әминевнең юашлыгы үз табигатеннән генә киләме? Бәлки, ул үз көченә ышанып та бетмидер?! Моның, минемчә, ике мөһим сәбәбе бар. Менә егерме ел инде актив иҗат итеп килүче талантлы драматург, «Язылмаган закон-

нар», «Тамырлар», «Умырзая чәчәкләре», «Гөлчәчәк» кебек бик киң таралган пьесаларның авторы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе турында юньле-башлы бер мәкалә, рәтле итеп язылган бер рецензия басылганы юк. Моның ояты да тәнкыйтьчеләргә төшә, эшем иясе булып, юктан барны тудырырга омтылып, субъектив тарлыктан чыгып кына кайберәүләргә урынлы-урынсызга «күренекле, фәлән-төгән» дигән исемнәр тагып йөргәнче, язып-эшләп килүчеләргә игътибарны көчәйтсәгез ярамас идеме?! Егерме ел иҗат өстендә утырган кешене күрмәмешкә салышу, аның иҗат портретын укучыга күрсәтеп бирмәү юашландырып кына калдырмас, иҗади торгынлыкка, кысырлыкка да китерер.

Икенчедән, драматургны драматург итә торган тагын бер шарт бар, ул да булса, язучының «иҗади төп йорты» — үз итеп санаган бер театры булырга тиеш. Театрсыз драматург — чын драматург түгел әле ул. Театр диюем, моңа режиссёр да, рәссам да, актёрлар да кирә.

«Юныс Әминев театрга кайчан аяк басты? Аның иң нәтиҗәле эшләгән еллары, танылган еллары кайчан?» дигән сорау куйсак, ул еллар Минзәлә театры «Сабир Өметбаев[1] театры» дип аталган еллар иде.

Дәртле чаклары иде Сабир аганың, егәрле еллары, канатланып эшләгән чаклары иде. Юныс Әминевне театр өчен ул ачты! Юныс башы-аягы белән Минзәлә театрының драматургы иде. Юныс Әминев белән бергә режиссёр булып Сабир ага үзе дә ачылды. Актёрлардан Фәсхетдинов[2], Җиһаншиналар[3] нәкъ менә «Язылмаган законнар»да уйнап халык арасында дан казандылар.

---

[1] Сабир Габделҗан улы Өметбаев (1908–1982) – Минзәлә татар дәүләт драма театрын оештыручы, баш режиссеры, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе (1960).

[2] Әнвәр Сәгъди улы Фәсхетдинов (1919–1995) – Минзәлә татар дәүләт драма театры актёры. ТАССРның халык артисты (1959), РСФСРның атказанган артисты (1976).

[3] Нәсимә Мансур кызы Җиһаншина (1926–2019) – Минзәлә татар дәүләт драма театры артисткасы. РСФСРның атказанган артисты (1957).

Әйе, Минзәлә театрының драматургы... Безнең күп авторлар мондый зур, мактаулы исемне ала алмадылар... Үз театрыңны табу, үзеңә фикердәш режиссёрга юлыгу, артистлар коллективына керү – бу драматургның үсүе өчен төп шартларның берсе. Бу – иҗат өчен бәрәкәтле җирлек, драматургның чынлыгы, кирәклеген раслаучы дәлил.

Гөрләп кенә барганда, Юныс Әминевнең тормышында байтак үзгәрешләр булып алды. Сабир ага Минзәләдән китте, аның урынына калган Мулланур Мостафин[63] эстафетаны кулында тота алмады, театрны уйнап кына да «Мостафин театры» дип атамадылар. Сабир ага үзе дә, Әлмәт театрына күчеп, Минзәләдәге атмосфераны тудыра алмады, егәре җитмәде, Юныс Әминев кебек драматургны, Минзәләдәге кебек актёрлар коллективын үзенә якынайта алмады. Әлмәт шәһәренә күчеп килгән Юныс Әминев бер түтәлдән икенчесенә күчереп утыртылган гөл кебек сулыбрак та калды. Әлмәт театрында режиссёрларның еш алмашынып торуы, килгәннәренең дә, «бүген китәм, иртәгә китәм» дип, алга карамыйча, килгән юлларыннан күзләрен алмавы аны беркадәр буташтырып та куйды.

Кайчагында гади, күзгә күренмәгән вак кына нәрсәләр дә яхшы әсәр тууын тоткарларга мөмкин, бигрәк тә сәхнә әсәрен. Автор никадәрле генә үзенчәлекле, талантлы булмасын, каләме кәгазь өстендә никадәрле генә җитез йөгермәсен – пьеса, спектакль булып сәхнәдә уйналганчы, бик күп күзләр аша уза, бик күп куллар аны капшап карый. Шул күзләрнең игелекле һәм таләпчән, шул кулларның җылы һәм нык булуы кайчагында хәлиткеч урынны ала.

Яңа пьеса, яңа спектакль кебек үк, күп очракта коллектив хезмәт ул.

Моннан ике-өч ел элек драмсекциягә, үзенең беренче пьесасын күтәреп, яшь драматург Диас Вәлиев килде. Пьеса фикеренең тирәнлеге, образларның масштаблы булуы белән безнең барыбызны да хәйранга калдырды. Татар драматургиясенә хәзер эшләп килүче драматургларның берсенә дә охшамаган яңа автор килде. Диас Вәлиевнең образлар системасы, сәхнә логикасы гаҗәп үзенчәлекле, күңеле сизгер, логикасы көчле, әйтергә теләгән фикерләре кирәкле һәм

мавыктыргыч иде. Яшь автор драматургларның бөтенсоюз киңәшмәсендә катнашты, пьеса анда да уңай бәя алды. СССР Язучылар союзының драматургия буенча секретаре Афанасий Салынский яшь авторның беренче әсәренә зур бәя бирде.

Автор театрга йөри башлады, секция эшенә актив катнашып китте, рецензияләр язды. Беренче пьеса кайбер сәбәпләр аркасында сәхнә күрә алмады, әмма Диас күңелен төшермәде, озак та үтмәде, икенче әсәрен тәмамлады. «Намус хөкеме» дип аталган бу пьесаның тууына кемнәр генә катнашмады! Культура министры Б. М. Гыйззәтуллиннан[1] алып өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин иптәшләр яшь автор белән кат-кат очраштылар. Әсәр турында, гомумән, тормыш, сәнгать турында файдалы әңгәмәләр алып бардылар. Секция бюросы һәм театрның художество советы пьесаны ике тапкыр укып тикшерде. Авторга тәҗрибәле язучы Гариф Ахунов сизелерлек ярдәм күрсәтте. Нәтиҗәдә яңа автор, яңа пьеса туды, театр гүзәл казанышларга иреште. Гомуми көч, уртак теләк гүзәл җимеш бирде. «Намус хөкеме» пьесасы РСФСР Культура министрлыгы тарафыннан башка театрларга да тәкъдим ителде, сүз арасында гына бу пьеса белән Мәскәүнең атаклы берничә театры кызыксынганны да әйтеп узарга кирәк.

Беренче пьесасына карата әйтелгән мактау сүзләре дә, тәнкыйть фикерләре дә авторны икеләндермәделәр, ул чын гражданлык хисләре белән янып, югары пафос белән иҗат итәргә кереште. Атаклы «КамАЗ» төзелеше кешеләренә багышланган «Дәвам итү»[2] дип аталган яңа пьесасы Д. Вәлиевне яңа югарылыкка күтәрде. Пьесаны Мәскәүнең Ермолов исемендәге театры, Казанда Качалов исемендәге рус драма театры куярга әзерли башлады. Менә без ымсынып, өметләнеп йөргән көн дә килеп җитә булса кирәк. Диас Вәлиевнең, Шәриф Хөсәеновның һәм Туфан Миңнуллинның яңа әсәрләре хәзер Мәскәү театрларында да кызыксыну уята-

---

[1] Булат Миңнулла улы Гыйззәтуллин (1920–1989) – журналист, 1961–1973 елларда Татарстан Республикасының мәдәният министры, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1970).

[2] Д. Вәлиевнең 1976 елда язылган пьесасы.

лар, ихтимал, без якын елларда ул авторларның әсәрләрен дә илебезнең башка бик күп сәхнәләрендә күрербез. Безнең бу авторларыбыз ил, дөнья югарылыгыннан торып иҗат итәләр, дөнья белән күзгә-күз сөйләшергә сәләтле, белемле һәм эшлекле авторлар.

Бүгенге көндә татар театрларында хәзерге заман сәнгате куйган барлык бурычларны үтәрлек дәрәҗәдә әзерлекле талантлы режиссёрлар эшләп килә. Марсель Сәлимҗанов, Празат Исәнбәт[1], Равил Тумашев, Гали Хөсәенов, Зәкия Туешева[2] иптәшләр, әдәбиятның көндәлек тормышына катнашып, авторлар белән эшлекле мөнәсәбәттә иҗат итәләр. Бу уңайдан Академия театрының баш режиссёры Марсель Сәлимҗановның эш практикасын күзәтү бик кызыклы.

М. Сәлимҗанов байтактан зур коллективны җитәкли, ул әдәбият, тормыш уртасында үз урынын белеп, кайнап яши, язучылар, әдипләр белән иң тыгыз элемтәдә тора. Үзенә кирәкне таба, аңлы рәвештә, ачык максат белән төп юнәлештә иҗат итә. Авторларның эш планнары аның өчен сер түгел, ул театрның эш планын авторларның киләчәк эшләре белән яраштыра, «яңа пьеса бар» дигәнне ишетүгә, аны табу чарасына керешә. Әйткән сүзендә тора, вакланмый, алдамый, коры, буш вәгъдәләр бирми. Булмастайны өстенә алмый. Талантсызларга, халтурачыларга ул аяусыз, шуның өчен йөзе һәрвакыт ак.

Барыннан да бигрәк Марсель Сәлимҗановның әдәбиятыбызның үткәненә гаять җитди мирас итеп карап, аның җәүһәрләрен берәм-берәм халык алдына чыгару практикасын хөрмәт белән искә алырга кирәк. Бөек Тукай исемен йөрткән премия, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Марсель Сәлимҗановка нәкъ шул юнәлештәге мактаулы эшчәнлеге өчен бирелде. Ул театр репертуарында классикларыбызның әсәрләрен күренекле бер урынга менгерде. Узган

[1] Празат Нәкый улы Исәнбәт (1927–2001) – актёр, режиссёр, педагог. ТАССРның халык артисты (1981), РСФСРның (1967) һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1986).

[2] Зәкия Хафиз кызы Туешева (1919–2018) – актриса, режиссёр, ТАССРның халык артисты (1969). 1966–1976 елларда Әлмәт театры режиссёры.

сезонда театр заказы буенча Гариф Ахунов Шәриф Камалның атаклы «Акчарлаклар»[1] повестен сәхнәләштерде. Шәриф Камалны Татар академия театрының тарихи сәхнәсенә яңа әсәр белән менгерү – үзе бер куанычлы факт булса, үзе дә драматург булган һәм театр өчен байтак хезмәт күрсәтеп килүче Гариф Ахуновның яңа яктан күренеп китүе – икенче бер күңеллелек булды.

Узган елгы сезонда тагын бер күңелле хәлгә юлыктык. Моңарчы безнең драматургларның бер үк әсәрен берничә театр күрсәтү фактлары бик сирәк очрый иде. Хәлбуки бу практика драматургларның иҗади үсешенә мәгълүм бер дәрәҗәдә файда да китерер иде. Ниһаять, ул торгынлыкка да чик куела башлады. Әлмәт драма театры Академия театрында баручы «Әни килде» пьесасын сәхнәләштерде. Марсель Сәлимҗанов үз чиратында Әлмәттә дөнья күргән «Диләфрүзгә дүрт кияү»не Г. Камал театрында күрсәтте. Бер үк пьеса. Бер үк материал. Ләкин ике театрда бөтенләй ике төрле спектакль туды. Әлмәт театры күрсәткән спектакльдә үз уңышы булса, Академия сәхнәсендә бу пьеса мюзикл булып, яңа жанр булып, күңелләрне очындырып яңгырады. Бу ике спектакльне чагыштырып карауны тәнкыйтьчеләр өлешенә калдырып, ике театрны да зур уңыш белән котларга кирәк.

Хәзер кемнәр нинди әсәрләр өстендә эшлиләр?

Академия театры портфелендә аксакалыбыз Мирсәй Әмирнең атаклы «Агыйдел»[2] повестеның сәхнәләштерелгән варианты ята. Шушы ук театр алдагы сезонда Сәет Шәкүровның[3] «Тол хатыннар, тол кызлар»[4] драмасын, Туфан Миңнуллинның «Ат карагы»н, Хәй Вахитның укытучылар тормышыннан алып язылган яңа әсәрен күрсәтәчәк. Илдар Юзеев Әлмәт театры өчен яңа пьеса тәмамлады. Диас Вәлиев тә шушы театр өчен яңа әсәр төгәлләп килә.

[1] Ш. Камалның 1914 елда язылган пьесасы.

[2] М. Әмирнең шул исемдәге повесте (1936) нигезендә куелган спектакль. 1974 елда әлеге сәхнә әсәре ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

[3] Сәет Габделхәй улы Шәкүров (1917–1989) – актёр, драматург. ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1970).

[4] Сәет Шәкүровның 1973 елда язылган пьесасы.

Күргәнебезчә, Татарстанда хәзер көчле, әзерлекле драматурглар эшли. Бүген өлкәннәр турында – Н. Исәнбәт, М. Әмир, Ф. Хөсниләр турында махсус тукталып тормадым. Аларның театрлар тормышына куйган ифрат зур хезмәтләре барыбызга да мәгълүм. Шуның өстенә аксакалларыбыз да тынмый, язалар, иҗат активлыгы белән яшиләр. Әмма, ни генә булмасын, кайсы яктан гына карасак та, театр репертуарының төп авырлыгы урта буын вәкилләренә һәм яшьләргә төшә.

Ю. Әминев, Ш. Хөсәенов, Хәй Вахитлардан соң байтак вакыт драматурглар сафы артмый торды. Ниһаять, Туфан Миңнуллин килеп керде, үз урынын тапты, үзенә юнәлеш алды. Аннан соң тагын тынлык. Хәзер Диас Вәлиевне, авыз тутырып, чын драматург дип атарга хакыбыз бар. Ләкин болар гына аз, бик аз бүгенге көнебез өчен. Театр институтларындагы, театр училищеларындагы талантлы яшьләрне шушы авыр, әмма гаять җаваплы һәм хөрмәтле эшкә тартырга кирәк.

**2**

Курчак театры турында бер-ике сүз.

Татар балалары өчен әлегә яшь тамашачылар театры юк. Аның функциясен өлешчә драма театрлары, өлешчә курчак театры үтәргә тиешле. Драма театрлары сирәк-сирәк кенә балалар өчен спектакльләр куеп куандырсалар, курчак театрыбыз чак-чак кына пыскып, сүнәр-сүнмәс кенә утыра. 1971 елда театр җитәкчеләре татар группасын икедән бергә калдырдылар. Театрның портфелендә байтак кына пьесалар булса да, алар, еллар буе игътибар күрмичә, шунда аунныйлар. Театр җитәкчеләре арасында татар драматургиясенә хөрмәт белән караган, аны белгән кеше юк диярлек.

**3**

Опера театры җитәкчеләре арасында да милли кадрларның булмавы соңгы елларда күңелсез нәтиҗәләргә китерде. Нәҗип ага Җиһанов әйтмешли, милли операларга мөнәсәбәт бик үзгәрде. Театр җитәкчеләре, нәкъ без алда кузгатканча, ялгыш фикердә торалар. Алар атаклы рус һәм классик опе-

раларны сәхнәләштерү белән бергә, сирәк-сирәк кенә булса да, милли әсәрләргә дә мөрәҗәгать итәләр. Һәм менә бу очракта түбән зәвыклы, арзанлы әсәрләрне сайлап алалар. Янәсе, шуның белән татар тамашачысын театрга тартмакчы булалар. Касса тутыру максатыннан чыгып кына эшләнә торган бу зарарлы практика башка театрлар тарихында булып, үз вакытында һәм хәзерге көндә каты тәнкыйтькә очрады инде. Милли операларның да нәкъ шул сәхнәдә куела торган әсәрләр белән янәшә барырлыкларын булдырырга кирәк. Әлегәчә кем әрсез, кем арткы ишекләрдән керә белә, шул Опера театры сәхнәсенә үзенең әсәрен үткәрә. Узган ел секция бюросында «Тылсымлы курай»[1] исемле опера-әкиятнең либреттосы тикшерелгән иде. Нигездә, төрле әкиятләрдән, сәхнәдә күп тапкырлар кабатланган мәгълүм әсәрләрдән, аннан-моннан йолыккалаган сюжеттан, таушалган образлардан гыйбарәт булган бу корама либретто бюро тарафыннан кире бәяләнгән иде. Бу фикер министрлыкка да җиткерелгән иде, әмма опера язылды, сәхнәгә дә куелды. Зарардан башка нинди нәтиҗәгә ирештек без?!

Опера театры белән бүгенге көндә уртак тел табу кыен.

**4**

Тамашачы, театр, драматург...

Шулар белән арадашлык итү бурычы тәнкыйтьчеләргә тапшырылган. Сүзне шуннан башлаган идек, шуның белән тәмамлыйк та...

Тәнкыйтьчеләрнең төрлеләре бар.

Өлкән тәнкыйтьчебез Гази ага Кашшаф, яшьләрдән Азат Әхмәдуллин[2], Ильтани Илялова[3], Роза Усманова[4], Дания

[1] Зәйнәб Биишеваның 1957 елда язылган пьесасы.

[2] Азат Гыйльмулла улы Әхмәдуллин (1932–2021) – әдәбият галиме, театр сәнгате белгече, тәнкыйтьче. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1982), Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (2002), Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе лауреаты (2014).

[3] Ильтани Исхак кызы Илялова (1932) – театр сәнгате белгече, тәнкыйтьче, сәнгать фәннәре кандидаты (1965). ТАССР-ның (1983) һәм Россиянең (2000) атказанган сәнгать эшлеклесе.

[4] Рауза Фатих кызы Усманова (1923–2014) – театр сәнгате бел-

Гыймранова[1] театрга һәм драматургларга эшлекле ярдәм күрсәтеп, даими элемтәдә торып эшлиләр. Бәян иптәш Гыйззәтнең эшчәнлеге генә бераз эчне пошыра. Гел кирәксезгә драматургларны үзара чәкәләштерү, яхшылыкка күз йому, бар нәрсәдән дә начарлык казып чыгарырга тырышу, уртакул авторларны һәм уртакул режиссёрны күккә чөеп мактау, аларның эшләрен алдан күрсәтү өчен генә башкаларны түбәнсетү, иң куркынычы – талантсыз кешеләрне җылыту кебек нәрсәләрне Бәян иптәштә еш очраттык без. Академия театрында барган бер генә спектакль турында да аның җанны рәхәтләндереп сөйләгәне юк. Соңгы ике-өч елда иҗади һәм финанс кризисы кичерә торган Минзәлә театрын тиктомалга гына иң алгы планга чыгарырга тырышуы да бу театр коллективына зарардан башка файда китермәде. Театр тәнкыйтендә мондый тар күңеллелек, субъективлык, яманны яхшы итәргә тырышу берчакта да яхшы нәтиҗәләр бирмәде.

Театр тәнкыйтьчеләребез үзәк матбугатта бик сирәк чыгалар, анда да һаман бер югарылыкта – информация бирү белән мавыгалар. Тәнкыйтьчеләр җыелышында «Мәскәү тәнкыйтьчеләре белән янәшә куярлык кешебез бармы?» дигән репликага урыннан, бик хаклы итеп, «Бар, бер генә – Рафаэль Мостафин!» дигән реплика ташладылар. Театр тәнкыйтенең Рафаэль Мостафины юк, ә ул бик тә кирәк иде. Безнең театр тәнкыйтьчеләренә зурлык, тирәнлек, театр тормышын җанлы процесс итеп, иҗади процесс итеп, өзлексез хәрәкәт итеп күз алдына китерү җитми. Бигрәк тә режиссёр эшчәнлегенә тирәнтен анализ ясалган мәкаләләр, рецензияләр аз. Бу уңайдан Дания Гыймранованың «Юләр кыз» спекталенә язган рецензиясе мактауга лаек. Режиссёр – хәзер театрда төп фигура, аның шәхесенә, шәхси сыйфатларына күп нәрсә бәйле.

Әйтик, Миргалим Харисов Риза Ишморатның «Хикмәтле Сәйфи» исемле әсәренә рецензия язып чыга. Минзәлә

---

гече, тәнкыйтьче. ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1968), РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1984).

[1] Дания Әхәт кызы Гыймранова (1937–2014) – театр сәнгате белгече, тәнкыйтьче. Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1997).

драма театры спектакле. Мин һәрбер рецензиядә язучы иҗатына тирән бер анализ ясалсын иде дип әйтмим, әмма Риза Ишморат кебек күп еллардан бирле драматургия белән шөгыльләнгән авторның яңа әсәре сәхнәгә менгәндә, аерата игътибарлы булырга кирәк иде. Беренче башлап, әсәрнең автор иҗаты өчен яңалыкмы-түгелме икәнлеге ачыкланса, икенчедән, театр өчен бу спектакльнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнлеге билгеле булсын иде. Рецензиядә Р. Ишморат әсәре аның моңарчы булган иҗатының дәвамы итеп каралмый, режиссёрның эшчәнлеге гомуми сүзләр белән генә әйтеп кителә. Ә бу әсәр турында байтак җитди сүз кузгатып булыр иде. Пьеса сиксән яшьлек Сәйфи картның яңа типтагы авылга күчәргәме-күчмәскәме дигән икеләнүләренә корылган. Әлбәттә, Сәйфинең күчәсе килми, шуның өчен аны «Җенле Сәйфи» дип атый автор. Спектакльдә Сәйфинең Җене дә бар.

Бүгенге көн өчен әһәмиятле мәсьәләме бу?

Әйе, яңа эксперименталь авыллар – бүгенге көннең актуаль мәсьәләләренең берсе. Ләкин беркемнең дә, өзеп кенә, киләчәктәге авыллар нәкъ менә Шапшыда төзелә торган авыллар төсле генә булырга тиеш, дип расларга батырчылыгы җиткәне юк. (Пьесада нәкъ әнә шул типтагы авылга күчү турында сүз бара.) Сиксән ел бер авылда гомер кичергән Сәйфинең күчмәскә теләве табигыйме? Табигый. Әгәр автор эреләндергән, шәһәр тибындагы авылларның бүгенге яшьләр психологиясенә никадәрле тәэсир итү проблемасын хәл итүне бурыч итеп куйса, мәсьәлә җитди, актуаль төс алыр иде. Ә болай карттан көлү, аны мыскыллау, йомшак кына итеп әйткәндә, бүгенге көн драматургиясенә берни дә өстәми. Рецензент М. Харисов исә өзеп кенә бер сүз дә әйтә алмый, пьеса һәм спектакль тирәсендә читтән-читтән генә каранып йөри...

Бүген безнең байтак звеноларыбызда талантлы, эшлекле кешеләребез бар. Культура министрлыгы һәм КПСС өлкә комитетының культура бүлеге драматургларга һәрвакыт ярдәм кулы сузып тора. Эшләгән кешегә юл һәрвакыт ачык.

Эшләгән эшләр шактыйдан булса да, алда эшләнәчәкләре тагы да зуррак, тагын да җитдирәк. Иҗат оешмалары ара-

сында контактларны тагын да ныгытып, аны принципиаль, коммунистик нигездә үстерә барырга гына кирәк. Безнең эштә икеләнеп торуларга, ялагайлыкка, күремсезлеккә һәм яла ягуларга, вак интригаларга, мин-минлеккә урын булмаска тиеш.

Зур чорыбыз бездән лаеклы әсәрләр сорый. Тормыш бер генә минутка тукталганны да, кәеф-сафа чигеп күзәтүләрне дә, үз-үзеңнән канәгать булуны да кичерми. Хәрәкәтнең генә бәрәкәтле икәнлеген онытырга һич тә хакыбыз юк. Илебез тормышында бара торган вакыйгаларның тышкы тасвирлары белән мавыкмыйча, аның эченә, үзәгенә, эчкәрге хәрәкәтләренә үтеп керергә кирәк, халкыбызның гүзәл уллары: эшчеләр, крестьяннар, интеллигенция вәкилләре турында онытылмас сәхнә әсәрләре тудыру – безнең бурыч.

Шәриф Хөсәенов, Хәй Вахит, Туфан Миңнуллин, Юныс Әминев, Диас Вәлиев, Шаһиморат Зәйни[1], Сәет Кальметов[2], Гөлшат Зәйнашева[3] һәм башка драматургларыбыз шул бурычны үтәү юлында торалар һәм армый-талмый шул юнәлештә эшлиләр.

*Казан, 1972*

## Үкенечкә калмасын![4]

Кем булырга? Нинди һөнәр сайларга? Һөнәр, дөрес табылган шөгыль – кешенең гомерен бизи торган факторларның берсе, әһәмиятлесе. Себер социологлары ун ел дәвамында унҗиде яшьлекләр арасында тикшеренүләр алып баралар һәм шактый кызыклы нәтиҗә ясыйлар: хәзерге заман үсмерләренең иң күпчелеге медицина фәне белән шөгыльлә-

---

[1] Зәйни Әхмәт улы Шаһиморатов (1913–1980), драматург.

[2] Сәет Гани улы Кальметов (1918–1992), драматург.

[3] Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева (1928–2005) – шагыйрә, язучы. ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1988), Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1991).

[4] А. Гыйләҗевнең 1982 елда язылган мәкаләсе. «Идел» журналында (2002, № 1) басыла. 6 т. «Сайланма әсәрләр»енең 4 т. кертелгән (2015, 167–176 б.)

нергә тели икән. Һәм тагы да кызыгы: икенче урынга... язучы булырга теләүчеләр күтәреләләр! Фән буларак медицина белән мавыгу хыялы күпчелек егет-кызларны биләгән икән, монысы аңлашылсын да, ди. Ә язучы булу?! Язучы булу — шактый катлаулы мәсьәлә! Беренчедән, аның өчен табигый талант кирәк. Талант — күрү сәләте, ишетү сәләте, башкалар аңламаганны аңлау сәләте, аңлату сәләте, йомгаклый алу сәләте, алдан күрүчәнлек, сиземләү — тагын бик күп, төрле-төрле компонентлардан тора ул «талант» дигән яңгыравыклы сүз! Даль бабай[1] «талант» төшенчәсен гади, әмма бик дөрес билгеләгән: «табигый сәләте булу» дигән. Димәк, талант бар икән — бар, юк икән — юк, бигайбә.

Бүген язучылык һөнәренең нечкәлекләре, аерым бер серләре, аның сөенечле һәм газаплы мизгелләре турында, иҗат процессының кайбер үзенчәлекләре турында бәйнә-бәйнә сөйләшеп булыр иде. Әдәбиятны аңлау белән бергә үзеңне дә аңлый барасың, әдәбият кануннарын үзләштерү бары тик эш, тәҗрибә белән, еллар дәвамында гына килә, дип раслап булыр иде, аны күп санлы мисаллар, дәлилләр белән беркетү дә читен түгел, байтак әсәрләр язылды, байтак өлкән әдипләрнең иҗат лабораториясен өйрәндем, мәгәр мин бүген үкенечләр турында сөйләргә телим. Байтак повестьлар, хикәяләр, пьесалар, роман язган кеше буларак, күңел серемне — үкенечләремне ачарга җыенам...

Моннан өч-дүрт ел элек, йомыш төшеп, төпчек улым Рәшат белән Арчага барып кайттык. Август аеның икенче яртысы, чалт аяз көн, җилсез, җылы, кырларда соңгы эшләр бара, туңга сөрәләр, чәчәләр, шунда ук салам эскертлиләр, кукуруз кырларында комбайннар йөри, янәшәдәге асфальт юлдан ашлык, яшелчә төягән машиналар узып тора, Казан — Арча поезды буш диярлек, алай да тукталыш саен кереп-чыгып йөриләр, татар агайлары, чибәр-чибәр апалар, җиңгиләр, әле тынгысыз студент халкы кузгалмаган, пассажирлар гел бериш, калага йомыш белән барганнары капчык-капчык калач, ипи күтәргәннәр, алма тутырган сеткалар да ялтырап-балкып кала; татарларга хас рәвештә басынкы гына сөй-

[1] Владимир Иванович Даль (1801—1872) — рус этнографы, фольклористы, лексикографы, язучысы.

ләшәләр; вагоннардан көнгә чыккач кинәт тавышлар үзгәрә, шатлыклы авазлар арта, сөенешәләр, кирә-килә оеган аякларын язып, тиз-тиз атлыйлар, киек казлар кебек тезелешеп, тимер юл янәшәсендәге руша[1] араларына, җылымса тузанлы юлларга, такыр серле сукмакларга кереп югалалар; берәүләрен ат көтеп тора, ялтырап торган кыйбатлы мотоцикллар янында алагаем чәч үстергән, күн итек кунычларын сыерып кайтарып салган көяз егетләр басып тора, алар кайтучылар кулыннан капчык-төенчекләрне йолкып алып эре генә бишекләргә ыргыталар да, кешеләрнең ныклап утырганын да көтмичә, шатыр-потыр кузгалалар. Күрсеннәр, янәсе, Казан арты егетләрен!..

Мин һәр юлаучыны күз белән озатып калам, аның кем булуын, нинди ашыгыч йомыш белән юлга чыгуын аңларга тырышам, кием-салымнарын, тотыш-кыяфәтләрен, йөз чалымнарын күзәтеп барам. Кузгалып киткәч тә, минем күзем гел тәрәзәдә, карыйм, ябырылып карыйм, аерыла алмыйм. Барган чакта түзгән булгандыр, кайтканда улым, тугыз-ун яшьлек үсмер, чыдамады, һаман тәрәзәгә ябырылып, йотлыгып, комарланып кайтуымны күреп:

– Әти, син ни күрәсең анда? Мин бер дә кызыгырлык әйбер күрмим,– дип әйтеп салды.

Җитди сорау иде бу, мәгънәле һәм бик тә урынлы сорау иде!..

Бер уйласаң, чыннан да, тирә-якта шул ук кырлар, шундый ук авыллар, юллар да бертөсле кебек, кешеләр дә заманча гади генә киенгәннәр, минем күзләр генә һаман карап туймый, нидер эзли, нидер таба иде. Әйе, дөньяны һәркем үзенчә күрә... Минем белән янәшә утырып, бер вагонда, бер үк тәрәзәгә карап баручы әби белән яшь кызның уйлары турында хикәя язасым килеп китте, чөнки беләм: һәркем үзе күрергә теләгәнне генә күрә. Әлбәттә, фантастик китаплар укырга яраткан, сугыш турында киноларны өзлексез карап баручы шәһәр малае өчен юл читендәге тын авыллар, гади тормыш манзаралары гел бертөрле, хәттә төссез, артык гади дә булып тоелганнардыр. Ә минем өчен як-ягыбызда су-

[1] Руша – кеше тарафыннан утыртылган агачлык, кечкенә урман.

зылып кала торган җирләрдә тормыш кайнап тора, күзем тәрәзәдә, уйларым шушы юл кебек өзлексез, мин әлләниләр күреп алам, бер сөенәм, бер кайгырам, йөрәгем дулкынланып тибә, мин үз җиремнән, үз юлларымнан, татар халкы өчен үтә дә газиз, үтә кадерле әдәби телебезгә нигез салган Казан артыннан узып барам ич. Алай гына да түгел... Бераз көлемсерәп баргач, мин улыма болай дидем:

– Бу тормыш әлегә сиңа ят! Ә мин һәр адымда, һәр сызыкта, ноктада гомерем буе күңелемне борчыган сорауларга җавап эзләп барам. Ничек яшибез без? Бүгенгебез ничек тә, ул иртәгәгә нинди тамырлар белән тоташа? Җир-суларыбыз ни хәлдә дә, кардәшләребез, милләттәшләребез ничек яши? Иң әүвәл мин юлларга карыйм. Сугыш елларында, сугыштан соңгы елларда юлларның теңкәгә тигәнен белсәң син!.. Юл шактый тар дөньяда яшәүче крестьянны киңлеккә алып чыга. Юл авыл кешесе өчен шулкадәр мөһим ки, авылның киләчәге, язмышы турыдан-туры юлларның ниндилегенә дә бәйләнгән. Кеше, киткән чагында, юлда чиләнә икән, ул инде бу юллардан борылып кайтмый. Әйбәт юл – кунак юлы ул, бәйрәм юлы, бәхет юлы! Кеше күңелен киң офыклар белән бәйләүче сызык ул авыл юллары!.. Юллар белән минем күзем авылларга барып керә. Ә авыллар берчакта да берберсенә охшаш түгел. Йортлар, урамнар, тыкрыклар да һәр авылда үзенчә. Әгәр авылда буш ихаталар, чокыр-чакырлы баз урыннары күп икән, димәк, монда нидер җитешмәгән, нидер килеп җитмәгән, урамнар тузып бара икән, гомумән, бу авылның хәле мөшкел, көннәре санаулы. Бу авылда җир белән кеше мөнәсәбәте өзелгән, йә монда яман хуҗалар булып киткән, крестьянның чын кадере беткән, бу авылга ашыгыч ярдәм кирәк! Ашыгыч ярдәмне авылга игеннең, җирнең, хезмәтнең кадерен белгән, киң күңелле, таләпчән, уңган һәм булган хуҗалар, тырыш кешеләр генә бирә ала. Һәйбәт авылларны күреп күңел сөенә, сөенеп кенә калмый, очына, яшәрә, иман ныгый. Һәйбәт, юан наратлардан, таза кирпечләрдән салынган алтыпочмаклы, верандалы йортлар, ак шифер түбәләр, бизәкле тәрәзә нәличникләре, чуклычәчәкле капкалар, бөтен җирдә сыерчык оялары, янбакчада гына түгел, ындыр түрендә дә, урам якта да уйдык-уйдык киң

ябалдашлы агачлар, бөдрә куаклар, терлек абзарлары, нык келәт-амбарлар, гаражлар, чиннекләр[1], төз лапас өсләрендә полиэтилен белән һәйбәтләп томаланган печән кибәннәре, парниклар, чәчәк түтәлләре, алтын шарлар, пәйгамбәр тырнаклары, инеш янындагы болыннарда нәни-нәни стадионнар, футбол капкалары, турниклар — һәммәсе күзгә рәхәтлек биреп, бу авыл кешеләренең нык куллы, тырыш икәнлеге, яшәү көче кимемәгәнен бөтен дөньяга кычкырып хәбәр итеп тора! Яңа йортлар ничәү?! Бер, ике, өч... җиде... ун! Димәк, бу авылда тормыш гел алга карый, су буйларын тутырып симез казлар йөри, үрдәкләр, ә урамнары тип-тигез, әле чирәм үскән урыннар да калган, тракторлар, яз-көз йөреп, изеп, җирнең маен сыгып сытып бетермәгәннәр. Димәк, бу авылда культуралы уйлаучан хуҗалар бар, бу авыл үзе үк кешене тәрбияли, аны бәхетле итә. Авылны сөенеп карап узганнан соң, бер кырыйдагы зиратка да күз салып өлгерәм мин. Каралганмы ул, койма-капкалары төзекме? Чардуганнар, борынгы ташлар ишелеп, күмелеп ятмыймы? Кәҗә-сарык, кереп, затсызлап йөрмимме? Агачлар кайчан утыртылган? Яшь агачлар күпме? Гомумән, таллы-тупыллы су буйлары, бәбкә үләне куерган инеш буйлары, алтын тәңкәләр таккан купшы каеннар, бәрәңге ызанындагы иләк башлы көнбагышлар, мең төрле үләннәрне киләчәк өчен саклап ятучы аулак тыкрыклар, авылның иң күркәм ноктасындагы һәйкәлләр, батырларга багышланган бу изге урындагы чәчәк клумбалары кеше рухын киңәйтеп, яшәешен бизәп, тормышына мәгънә өстәп торалар! Шыр ялангач зиратлар, уттан калган төсле буш урамлы авыллар, кантарлы ятим юлларны күргәч, йөрәк әрни, монда яшәүчеләр белән бергә йөрәк сыкрый. «Нигә алай? Җаннары кайда соң боларның?! Башка төбәкләр гөрләп утырганда, нигә күңелләре суынган боларның? Бу уңдырышлы, бәрәкәтле җирнең чын хуҗалары калмаганмыни соң?» — дип борчыласың. Урын юллардан пошкырып атлар узганын күрсәм дә сөенәм мин, ат ул — тормыш мисалы, тереклек мисалы, кешелекнең мең еллардан килгән иң тугры дусты. Инде елтыр сыртлы көр бияләр янында ефәк койрык-

[1] Чиннек — эш кораллары саклана торган һәм шул кораллар ярдәмендә җиһазлар ясау урыны.

ларын яшьлек байрагы итеп болгап йолдыз кашка колыннар да чабып узса... күңелләр тула, сөенечтән күз яшьләрем сытылып чыга... «Бар ул аңлы хуҗалар, бар ул тормышның киңлеген бөтен барлыклары белән сизүче кешеләр»,– дип чиксез куанасың...

Татар авылы манзарасы – такыр юллар, хәтфә буа буйлары, келтерәп утырган ике, өч ташлы тегермәннәр, сиртмәле коелар, урам якка капка төбенә куелган шома эскәмияләр, ындыр түрендә басынкы гына зәңгәр төтен таратып утырган мунчалар, тыкрык тамагына тезелгән юан, биек-биек тупыллардагы төнге карга ярминкәләре, келәт алдына сибелгән чыпчык-күгәрченнәр, кече якта әле генә мичтән чыгып тезелешеп утырган кайнар ипиләр, болар – кичәгенең генә түгел, бүгенгенең дә, алдагы көннәребезнең дә аерылмас төсмерләре.

Казан арты авыллары Тау ягы авылларына охшамаган, безнең Кама аръягы авыллары үзгә төстә. Шулай булсын! Шулай булып мәңгегә калсын!..

Туган җиремнең һәр почмагына, һәр сукмагына, юлларына, урман авызындагы чүнниктә тезелешкән умарталар янында кайнашкан ак сакаллы, ак күңелле картларына карап та, мин әллә нинди тирән, файдалы, дулкынландыргыч уйлар уйлый алам, туган җиремнең җитеш яки җитешсез яклары мине һәр мизгелдә, һәр адымда аерым киеренкелектә тота, кая карасам да, минем күңелемә җылы рәхәтлек, татлы, кабатланмас бәхет тула, мине баета, һәр очраган кеше минем иң якын кардәшем, дип сөенәм, безнең иң газиз, иң бөек, иң кадерле нәрсәләребез – җиребез, телебез, табынган бөек кешеләребез уртак, шушы җир белән, шушы җир хуҗалары белән шулай үтешли генә, ашыгыч очрашу да минем гомеремне озайта, яшәвемнең эчке мәгънәсен билгели. Шушы тын авыллар, шушы кабатланмас төсләр белән тулы кырларга карап, мин рухыма көч алам! Шулар тормышы, бәхете өчен көрәшәм! Иң мөһиме: мин бернигә дә битараф түгел, ничәшәр мәртәбә очратсам да, ничә мәртәбә шушыңа охшашрак манзараларга күзем төшсә дә, мин аларга һаман әсәренеп карыйм, яратып карыйм, сөенеп карыйм, борчылып карыйм. Иле-теле булу – кеше өчен иң зур, иң олы байлык. Моннан

да өстен байлык берчакта да була алмаган. «Байлык – бер күнлек» дигәннәр борынгылар, ә бу байлык – мәңгелек, кабатланмас байлык. Халыкка бер генә тапкыр бирелә торган кадерле байлык. Без моны бер генә көнгә түгел, бер генә минутка да онытырга тиеш түгел.

Мин боларның барысын да ул чакта, Арча – Казан поездында, төпчек улыма сөйләдемме-юкмы – хәтерләмим, әмма уйлаганым, күңелдән уздырган кичерешләрем шул иде. Үзең үскән, үзең йөреп, адымнарың белән иңен-буен мең кат үлчәгән, күз күнегергә тиеш булса да, һаман күнекмәгән авыл-кырларның, урман-юлларның һәр ноктасына гомерең буе – яшьлектә дә, картлыкта да әсәрләнеп карый ала белү, алардан мантыйк һәм мәгънә табу, үткәндәгене һәм киләчәкне бүгенге белән бәйли алу, һәр гади кешенең язмышы шушы илгә, шушы җир вакыйгаларына бәйләнештә бер дә гади түгеллеген, бөеклекнең гадилектә икәненә инану – язучы өчен иң беренче, иң мөһим шарт, дип исәплим мин...

Минем үземдә язучылык дәрте иртә уянды. Өченчедә укыганда, шигырьләр яза башладым, дүртенче класста «Отличник» исемле поэма яздым. Хикәя-пьесаларны бишенчедә яза башладым, «Ул үскәндә» исемле повестьны да шул ук елда кәгазьгә төшердем шикелле. Шулай да беренче җитди «әдәби елым» итеп 1945 елны исәплим. Университетта, әдәбият түгәрәгендә «Йөрәк тынычсызлана» исемле хикәямне укыдым. Хикәя ерак Украинага, мин бер тапкыр да аяк басмаган, күрмәгән-белмәгән җирләрдә яшәүче украинлы Матвей картка багышланган иде.

Ни өчендер мин яшьрәк чагымда үзебез яшәгән тормыш артык гади, кызыксыз һәм тонык дип санаганмын, ахрысы... Дөрес, минем беренче җитди хикәямнең Украина җиренә багышлануының төпле бер сәбәбе дә бар иде, ул – сугыш! Сугыш безнең бөтен барлыгыбызны билгеләп, безнең яшьлек елларыбыз белән янәшә барды. Һәм чын тормыш, катлаулы тормыш – кешеләре, вакыйгалары белән әдәбиятка керергә, сәнгатьтә урын алырга хаклы тормыш кайдадыр еракта, читтә, Украинада яки Белоруссиядә генә, безнең тормышта әдәбиятта дәрәҗә алырлык хәлләр дә булмый, без артыгы белән гади яшибез, дип уйлаганмындыр, күрәсең,

икенче хикәям – «Лира чыңлый» да Ерак Көнбатыш хәлләренә атап язылган иде.

«Күзеңне ачып кара, син бит кабатланмас тормыш эчендә кайныйсың, син энҗе-мәрҗәннәр чәчелгән җир өстеннән түгел, ата-бабаңнарның каны коелган, күз яше түгелгән кыр-юллардан узасың, монда синең бишегең, туган телең ныгыган урын, халкыңның акылы-фигыле чәчәк аткан нигез, тирә-ягында гаҗәеп кешеләр, моң, әкият-җырлар, акыл-гыйбрәт, гореф-гадәтләрең, зиратларың! Син шуларны аңларга тырыш!» – дип, берәү дә өзеп әйтмәде микәнни?! Әллә гел офык аръягына омтылган күңел күзем артык сукыр булдымы? Башкалар башкача яшәп, мин алардан читтә сөрлегеп калдыммы, адаштыммы, саташтыммы?!

Әллә бөек Тукаебызның, җан ачысы белән сөенеп:

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.
Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...[1] –

дип әйткән сүзләре безнең колакка чынлап торып килеп ирешә алмадымы ул чакта?! Безнең колак төбендә әллә башка, ят чикерткәләр, артыгын сайрап, юри саңгыраулandырып тоттылармы, белмим...

Хәзер уйлыйм да шаккатам... Нинди катлаулы язмышлы гүзәл кешеләр арасында яшәгәнмен икән! 1940 елларның азагы. Мин Зәйдә, комсомол райкомында эшлим. Квартирада Ксения Фёдоровна Роксман дигән карчыкта торам. Мәлем авылының керәшен кызы ачлык елларда Ленинград яһүде Роксманга кияүгә чыга да Ленин шәһәренә[2] китә. Яши. Блокада елларын кичерә. Сугыштан соң Зәйгә кайтып, җимерек, кырык терәүле өй һәм Машка исемле кәҗә алып, берьялгызы гына яши башлый. Бик күп рус романсларын, опералардан арияләрне белүче бу ярым сукыр карчыкта яшәү көче тыелгысыз күп иде!.. Ленинград блокадасын башыннан уздырып исән калган кеше... Ничек барып чыктың икән син ул шәһәргә?.. Нигә? Ничек таныштыгыз сез Роксман белән?! Ниләр кичердең син авыр сугыш елларында?.. Ничек исән

[1] Г. Тукайның «Пар ат» шигыреннән өзек.

[2] Ленинград, хәзерге Санкт-Петербург.

калдың?.. Әйе, бу сорауларга мин җавапны үзем эзләп таба алам. Ә Ксения Фёдоровнадан сорый алмыйм, ул юк, ул бу дөньядан күптән күчкән, очрашу елларында мин бу сорауларымны бирә алмаганмын, бу сораулар дәрәҗәсенә өлгереп җитмәгәнмен, энҗе чәчелгән кырлардан атлап йөрсәм дә, энҗеләрне иелеп ала алмаганмын!.. Күпме алар, минем язмышыма, тормышыма кагылып, мине баетырга әзер булган бай язмышлы кешеләр!.. Теләнче Тамак авылында, 1945 елның май – июнендә, унынчы класска имтихан биргәндә бергә квартирада торган зоотехник Зәкуан Шәйдуллин!.. Нинди күтәренке күңелле, сынмас рухлы якты кеше иде ул!.. Нигә күбрәк сорашмаганмын? Нигә кызыксынмаганмын? Нигә истәлекләрне, көндәлекләрне язып бармаганмын?! Һәр атна ахырында Зәкуан Шәйдуллин, Ватан сугышы инвалиды, өс-башын гаять пөхтә йөртә торган, барлык паёгын кече энекәшләренә, сеңелләренә алып кайтып китә торган, үзе «безгә кояш нурыннан тигән витамин да җитә!» дип ярым ач яшәсә дә, һәрчак көр күңелле, җырчы, моңлы кеше... Нинди уйлар уйлап уздың икән син авылыгыз юлларыннан?! Нигә бер тапкыр да сорашмадым икән мин синең күңел серләреңне?!

Зәйдә эшләгәндә, телефончы кызлар – апалы-сеңелле Лида һәм Валя Вжесневскаялар белән таныш идем. Поляк кызлары, ятимәләр. Каян килеп чыкканнар алар Зәй төбәгенә? Нигә? Сорашылмаган... Баксаң, гаҗәеп язмышлар бар икән анда! Былтыр кайтып, Зәй төбәгендә полякларның байтак булуын, аларның элеккеге политик сөргенгә куылган билгеле фамилияләрдән килүен сорашып белештем...

Күпме кызыклы кешеләр, катлаулы язмышлар, фаҗигаләр, гыйбрәтләр яныннан узып кителгән. Күпме моңнар, җырлар, кызык сүзләр янәшәдә генә түгелеп калган. Ярый, акыл килеп, сугыштан соңгы елларда биш йөзгә якын кыска җырларны теркәп куйганмын... Мин керәшен авылында үстем. Баграж керәшеннәренең йола җырлары, үзенчәлекле телләре, күңел юмартлыклары, бәйрәмнәре, туйлары... Нардуган уеннары, кырау куулар, йөзек салышлар! Никадәрле мәгънә, тапкырлык, җорлык бар иде аларда... Юк, язып куелмаган. Хәтер исә – тишек иләк, күбесе онытылган, күбесе чуалган... Авылым картлары! Сәвәләй Питере – Аучы һәм

Әкиятче – тере бүре тотып кайтып безне шаккатырган гаярь кеше. Нигә ачыграк күз белән карамадым икән мин сиңа?! Үтәми дәдәй, Кара Питер, Аксак Ибан, мәктәп завхозы Җәпүш дәдәй, Җаграп, Озын Микәйлә!.. Нинди кешеләр булгансыз сез!.. Түкмәт Пумасы, Чыпчык Пауал! Чыжык Бәчелие!.. Кунун Ладимиры! Җәмәк Әндрие! Классташым Җәкәү!.. Күбегез сугыш кырларында ятып калды... Мин күрдем бит сезнең гомерне!.. Мин сезнең язмышка шаһит... Үз вакытында сезнең сүзләрнең кадерен белмәгәнмен. Дөньяның мәгънәсен е247047актан, читтән эзләгәнмен!..

Дөрес, күңел бик күп нәрсәләрне үзенә җыеп алган, беркеткән, онытылмаслык иткән, алай да соңгы елларда мине олы үкенечләр газаплый: үткәннәремә борылып караган саен, уйланган саен, мин нидер җитмәгәнен тоям, нидер калган, онытылган, мин генә түгел, аларны башкалар да оныткан, бик күп кешеләрнең язмыш чишелеше тирәнтен уйланылмаган, җырлар онытылган, моңнар күмелгән, гореф-гадәтләрнең кабатланмас үзенчәлеге инде сакланмаган, эзләсәң дә юк... Археологлар чүлмәк китеге табып та, аны фән ярдәмендә бөтәйтә алалар. Тәтәй ватыгыннан чыгып, еллар, ун еллар, гасырлар турында фикер йөртә алалар. Сүзләр онытыла икән – алар табылмый, җырлар онытыла икән – алар яңадан туачак түгел, гадәтләр, уеннар, тел ярышлары – һәр заманның үз төсмере белән туа да югала икән! Кара мунчалар безгә кызыл почмак булды, Яңа ел тирәләрендә яшьләр, җыелып, йөзек салышалар иде. «Йөзек миндә, җыр кемдә?» дип әйтеп, сулы чиләктән йөзек тартып чыгарганда, нинди җор сүзләр, кабатланмас тапкыр җырлар әйтелә иде. Вакыйгасы истә, бәкегә суга төшкәндә, көмеш ай нурына күмелгән карлы сукмаклар истә, ә җырлар, уен сүзләр онытылган. Сорашып карасам да, аларны хәзер берәү дә белми... Җырларның ватыклары калмый, җыр ватыгыннан моң чыгарып булмый!.. Нинди үкенеч!

Әйе, беренче хикәяләрем ерак офыкларга, мин күрмәгән, мин белмәгән җирләргә, мин аңламаган кешеләргә багышланса да, мин бу чирдән тиз айныдым. Соңгы повестьларым: «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят»[1], «Язгы кәрван-

[1] А. Гыйләҗевнең 1972–1973 елларда язылган повесте.

нар»[1], «Җомга көн, кич белән...» һәм башкалар минем изге туфрагыма, туган илемә, торган җиремә, мин күргән, мин сөя белгән, мине баеткан, яшәү куәте биргән җирдәшләремә багышлана. Язучы фантазиясе никадәрле бай, нихәтле юмарт булмасын, тормыш аңа караганда мең тапкыр баерак. Тормыш – фикер чыганагы, тормыш – язучы күңелен әйдәүче-җитәкләүче көч ул. Минем геройларымның күбесе миңа таныш кешеләр. Дөрес, мин аларны фотога төшереп, гадиләтеп маташмыйм, күңел аларны үзе баета, үстерә, тирәнәйтә ала, әмма һәр очракта да мин туган җиремә таянам. Үзем йөргән юлларда йөри минем кешеләрем, үзем кичергәннәрнең төрле формаларын кичерәләр алар. «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят»нең соңгы бүлекләре сугыштан соңгы елларда Чехословакиядә һәм Украинада тәмамлана иде. Бу бүлекне мин читенлек һәм бик авырлык белән яздым. Бастырып чыгарсам да, повестьның ул соңгы бүлекләрен ярата алмадым. Чөнки мин үзем белмәгәнне, үзем күрмәгәнне язган идем. Русчага тәрҗемә иткәндә, мин ул бүлекләрне алып ташладым, повестьны өр-яңадан язып чыктым, юлын юлга русчага да үзем тәрҗемә иттем...

Берзаман минем янга Хәмис Яһүдин[2] килеп керде. Өч-дүрт пьеса язарга өлгергән икән, пьесаларының икесе Америка буржуаларын фаш итүгә багышланган, өченчесе Вьетнам вакыйгаларына катнашып китә. «Кем булып эшлисең син, Хәмис?» – дип сорадым. Эшче яшьләр тулай торагында тәрбияче икән... Үзе белгән, үзе аңлаган, үз күңелен борчыган вакыйгаларны ни өчен океан артыннан эзли Хәмис? Нигә ялгыша? Әллә без яшьләребезне үз җиребезне кадерләрлек итеп тәрбияли алмыйбызмы? Нигә алар читкә тайпылалар? Без Хәмис белән бу турыда бик ныклап сөйләштек, мин аңа үз үкенечләремне сөйләп тә бирдем шикелле.

Әйе, хак, үзең күрмәгәннәр турында да язарга ярый. Ярый гына түгел, кирәк. Мәсәлән, заманыбызның иң зур язучыларыннан берсе Нурихан Фәттах – атаклы романчыбыз – тарихның әллә кайда еракта калган катламнарына таянып

[1] А. Гыйләҗевнең 1972 елда язылган повесте.

[2] Эсфир Яһудин (Хәмис Шәмсегали улы Яһудин, 1949–2022) – язучы.

эш итә. Монда эш башка. Нурихан Фәттах – үзе яза торган чорның иң зур галиме, ул чирек гасыр гомерен шул чорны өйрәнүгә багышлады, аның искиткеч бай китапханәсе бар, ул археологик экспедицияләргә катнашты, үзе яза торган өлкәләргә сәяхәт ясады, үзе яза торган заманда ул балык кебек йөзә, тел-лексик материаллары тупланган, ул үз өстенә алынган эшнең никадәрле мактаулы, авыр һәм җаваплы икәнен белеп эш итә. Мактау һәм дан аңарга! Шуны да өстәп әйтергә кирәк: Нурихан Фәттах тарихыбызга да бүгенге көн зарурлыгыннан чыгып тотынды, бүгенге көн таләпләре аны тарихи романнар тудырырга дәртләндерде, һәм бу – аның әсәрләренең уңышын тәэмин итте, әдәби кыйммәтләрен арттырды.

Әйе, үткәннәрне белү кирәк.

Әйе, киләчәк турында уйларга, кайгыртырга кирәк.

Әйе, чит җирләрне, чит халыкларны, чит дөньяларны танып белү зарури. «Чит илләрдә йөреп гыйбрәт ал!» дигәннәр борынгылар...

Тик язучы үзенең беренче ныклы адымнарыннан ук, беренче җитди сүзеннән үк тирә-ягына, халкына, җирдәшләренә, милләттәшләренә үткен, уйчан күз белән карарга өйрәнсен. Чөнки туган телне белү, аның кадерле җәүһәрләрен барлау, әсәрләрендә аны туплау, ныгытып калдыру – язучының төп бурычларыннан берсе. Танып белү яшьлеккә хас. «Картаеп каткач буыннар, эш белү уңайсыз ул!»

Язмышлар, характерлар, вакыйгалар – безнең үз тирәягыбызда. Башкалар күрмәгәнне күрә алу, аңлау һәм аңлата алу, үз туган җиреңнең һәр ноктасына әсәренеп карый белү – язучының да, укучының да төп бәхете. Язучы белән укучы нәкъ әнә шул меридианнар кисешкәндә очрашалар, нәкъ әнә шул ноктада аңлаша алалар. Язучы белән укучы арасында фикер берлеге бары тик әнә шул очракта гына туа, ныгый.

Туган җирең кешеләренә карап төрле уйлар уйлый алу – нинди олы һәм кабатланмас бәхет ул.

*Казан*

*1982, сентябрь*

# Җан авазы[1]

Татар әдәбиятының горурлыгына әверелгән «Тайгак кичү» романының басылып чыгуына елга якын вакыт үтеп китте. «Казан утлары» романны басарга әзерләгәндә, мин яшь һәм урта буын тәнкыйтьчеләре җыелган бүлмәгә кереп: «Роман дөньяга чыгу белән аны күтәреп алырга кирәк иде, укучылар арасында киңрәк таралсын, аңласыннар, уйлансыннар, «Тайгак кичү»[2] – илебездә гаделлек, хаклык һәм хәбәрдарлык өчен тартышта тутыкмас корал ул!» – дип, үземчә, үгет биргән идем. Шул көннәрдә Татарстан китап нәшрияты үтенече белән әсәргә кереш сүз язып, аны «Җан авазы» дип атадым. Шөкер, шушы елның март башларында роман алтмыш дүрт меңлек тираж белән дөньяга чыгып та җитәчәк.

Сиксән сигезенче ел дәвамында байтак газета-журналлар романга теләктәш мөнәсәбәтләрен белдереп өлгерделәр, безнең республика газеталарында урыс һәм татар телләрендә күләмле өзекләр басылды, Ибраһим ага Салахов яшәгән Казакъстан матбугаты да кузгалыштан читтә калмады, казакъ һәм урыс телләрендә авторның якташлары татар әдәбиятының казанышлы үрнәге белән таныштылар. Казакъстанда чыгучы «Простор» журналы «Тайгак кичү»не тулысынча бастырып чыгарачак. Болай, бер караганда, роман-хроника замандашларыбыз күзеннән читтә калды дип рәнҗергә дә ярамас! Мәгәр бер нәрсә күңелне гел тырнап тора: романны укыган тәнкыйтьчеләр, әдәбият осталары, сүз куешкандай, нигә авызларына су каптылар? Әсәрне әтрафлы һәм нигезле тикшерү дә, аны гомумсовет әдәбиятында бара торган бәрәкәтле агымга кушып җибәрү дә – берсе дә эшләнмәде. Ни өчен? Ни булды? Күңелгә шик-шөбһәле уй да килеп китә: безнең абруйлы өлкән һәм өметле яшь тәнкыйтьчеләребез тормышның мондый кискен үзгәрешенә әзер түгелләр идеме? Алар күңелләрендә ныгыган принципларына «Тайгак

[1] Гыйләҗев А. Җан авазы. [Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү» романын укыганнан соң туган фикерләр.] // Социалистик Татарстан.– 1989.– 26 февраль.

[2] И. Салаховның 1988 елда «Казан утлары»нда басылган романы.

кичү» романын яраклаштыра алмадылармы? Әллә инде як-якларына каранып, «Бүген болай болаен, иртәгә ни булыр?!» дип, өркеп үк калдылармы? Кайда безнең әдәбиятларны айкаган Рафаэль Мостафиныбыз? Тәнкыйтьчеләрнең атасы Мансур Вәлиев кайда? Мыек астыннан гына көлемсерәп йөрсә дә туры сүзле, тапкыр телле Салих Маннапов[1] ник дәшми? Ренат Мөхәммәдиев, Тәлгать Галиуллин[2], Азат Әхмәдуллин, Флүн Мусин кебек бүгенге татар тәнкыйтенең баганалары нигә сүзсез калды? Фоат Галимуллин[3], Әхмәт Сәхәпов[4], Фәрит Хатипов[5]лар да заманга һәм илдәге үзгәрешләргә туры мөнәсәбәтләрен шушы әсәр аша белдерә алмаслар идеме? Дөрес, һәр язучының берничә еллык иҗат планнары булган кебек, тәнкыйтьчеләрнең сандыгы да буш тормыйдыр, алар әдәбият аша заманны, дәверебезнең иң кискен куелган мәсьәләләрен халкыбызга аңлатырга тырышып, зарурияте көннән-көн ныграк сизелгән мәкаләләр, монографияләр язып утыралардыр; тормыш бәрәкәтле хәрәкәт сорый, әдәбият белгечләребез дә шәхси әңгәмәләрдә, кулуарларда, таррак җыелышларда үткен-үткен фикерләр әйтеп,

[1] Мөдәррис Харис улы Вәлиев (Салих Маннапов, 1953–2020) – әдәбият тәнкыйтьчесе, журналист, язучы, 1992–2009 елларда «Мәгариф» нәшрияты директоры. Татарстан Республикасының атказанган мәдәният эшлеклесе (1989), М. Җәлил исемендәге Республика яшьләр премиясе лауреаты (2003).

[2] Тәлгать Нәбиулла улы Галиуллин (1938) – әдәбият галиме, язучы, филология фәннәре докторы (1981), Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы (1998), Татарстанның, Россиянең атказанган фән эшлеклесе (1993, 1999).

[3] Фоат Галимулла улы Галимуллин (1941) – әдәбият галиме, тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы (1990), профессор. Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (1996), Язучылар берлегенең Җ. Вәлиди исемендәге премиясе лауреаты (2005).

[4] Миңнәхмәт Җәмил улы Сәхапов (1957–2020) – тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният эшлеклесе (1996), Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (2003).

[5] Фәрит Миргалим улы Хатипов (1930–2020) – әдәбият галиме, тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы (1985), профессор. Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (2000).

җәмәгатьчелекне еш кына таң калдыралар. «Тайгак кичү» романына нисбәттән дә аларның бик төпле, нигезле йомгак ясауларын ишеткән бар. Нигә бу хакта үзәк матбугатта язып әдәби хәрәкәтебезне бер баскычка югары күтәрмиләр дә, үзләрендә туган фикерләрне әдәбият сөючеләр белән уртаклашмыйлар?! Гаҗәбрәк һәм сәер тынлык бу! «Юк бездә, юк!» дип зарланабыз да, булгач, канатларыбыз сәлперәя, тавышыбыз тоныклана.

Ибраһим Салахов Күкчәтауга якын гына Кызыл Яр карьясында яшәп ята, өч инфаркт кичерсә дә, сиксәнгә якынлашып килгән аксакал Яңа ел алдыннан Татарстанга килеп китте, ата-бабаларының туган төяге Казан артына, шанлы-шөһрәтле Балтач районына сәяхәт ясап, асыл якташлары белән очрашып кайтты. Очрашуларның берсендә мин дә катнаштым. «Тайгак кичү» әсәренең халкыбыз арасына бик тирән үтеп кергәнлеген шунда күрдем. Роман басылган журналлар кулдан-кулга йөреп теткәләнеп беткән, китапханәләрдә озын-озын чиратлар тезелгән. Каһәр суккан, тенкә корткыч чиратлардан җәфаланган булсам да, бу чиратларны белгәч күңелем күтәрелде: «Бар икән әле татар халкы, яши икән, укый икән, өметләнә икән!» – дип куандым. Очрашуларда укучыларның активлыгына мин таң калдым! Роман халкыбызның сүнеп барган хисләрен уяткан, мең-мең төрле сораулар тудырган, илебезнең сәяси хәле дә, партия тормышында булган үзгәрешләр дә, халкыбызның һәм туган телебезнең бүгенге һәм киләчәк язмышы да, халкыбызны халык итеп саклап калуда күп вакытлар бердәнбер терәк булып торган мөселман диненең фәлсәфи эчтәлеге дә, Идел-Нократ буйларының экологик хәле дә, татар мәктәпләренең аяныч язмышы да, тагын бик күп, үткен һәм хәвефле сораулар били икән Казан артында көн күрүче кадерле милләттәшләребезне! Без район, авыл советы, колхоз җитәкчеләрен дә күргәләдек. Алар да элекке сыман бер-берсенә шигәеп карап тормадылар, күкрәк кагып, горурланып: «Без – татарлар... ил алдында безнең йөзебез якты! Без бер халыктан да ким түгел!» дип уй йөртәләр, уйлаганнарын кыю рәвештә халык алдында чыгып-чыгып та әйтәләр. «Болгарлар – безнең борынгы бабаларыбыз, нигез тамырыбыз, без – татарлар!» ди-

гәч, Куныр авыл клубына җыелган зирәк халык аягүрә басып озак кына кул чапты. «Якты юл» колхозы рәисе Хәмит Гәрәевнең заманча фикерләрен ишетеп, үзе белән якынрак танышкач, куанычымның чиге булмады. Ибраһим ага белән: «Әле җитәкчеләребез арасында да татар җанлы кешеләр бар икән!» – дип, кат-кат сөйләштек.

Әгәр партиябез үзгәрешләрне башлап җибәреп, илдә хөрлек, гаделлек игълан итмәсә, әгәр совет әдәбиятында, матбугатта меңнәрчә мисаллар белән яшәешебезгә, үткәннәргә чын тарихи бәһаләр бирелмәсә, Куныр халкында шундый куанычлы уяныш, күтәрелеш булыр идемени?! Әгәр «Тайгак кичү» кебек романнар халык аңына рух ирегенең ни икәнлеген китереп җиткермәсә, без, ничәмә-ничә еллар ярым кол хәлендә яшәгән халыклар, бүгенге үзгәрешләрнең кыйммәтен тулысынча кабул итә алыр идекме икән?!

Әдәбиятның, сәнгатьнең, аерым бер әсәрнең көче кайчагында бәя биреп бетермәслек була, аларның көче, җегәре елдан-ел арта, ул меңнәрнең яшәү чыганагына әверелә. Мин, «Тайгак кичү» роман-хроникасы – әдәбиятның иң югары, данлы ноктасы, дип расларга җыенмыйм, ул бөтен яктан камил, мөкәммәл дип тә бармыйм, мәгәр роман бүгенге тартышларның иң алдынгы сызыгында яши, эшли, көрәшә. Бу фикерне роман авторына яуган йөзләрчә хатлардагы мисаллар белән дә раслап булыр иде. Укучыларыбыз роман басылып беткәнне дә көтеп тормадылар, алдагы саннар чыгуга ук, Ибраһим ага Салаховның адресын белеп бетермәсәләр дә, хатлар яудыра башладылар. «Көн саен алты-җиде хат килә, журнал илнең бөтен почмакларына барып җитә икән, хатларга җавап биреп кенә өлгерә алмыйм», – дип, кат-кат язды Ибраһим ага. Һәм ул килгән хатларның бер өлеше белән мине дә таныштырды һәм «шуларны файдаланып газета укучыларына мөрәҗәгать итсәң икән!» дип, үтенечен дә белдерде.

Телевидение аша Ибраһим ага белән уртак чыгышыбыздан соң миңа да хатлар ешайды... Иң әүвәл Лениногорск шәһәреннән килгән Зиннур Таҗиев хатына игътибар итик әле.

«1947 елда бер гаепсезгә кулга алып, 58 нче статья белән ун елга ябып куйдылар. Лагерьларда, этапларда, төрмәләрдә нинди газаплар күргәнне язып бетерерлек түгел! Чита КГБ-

сында җир астында бер башым дүрт ай ярым утырганны языйммы?.. Амур өлкәсендә Тахтамыкта дигән станца бар. 1947 елның июлендә шушы станца янындагы лагерьга китерделәр. Лагерьда 1200 актировать ителгән хәлсез тоткыннар ята иде. Алар шунда җәфаланып үлеп беттеләр... Шул елларда мин Индигарка аша күпер сукканда катнаштым. Адыгалахтан Хандыга чаклы 650 чакрым тимер юл салдык. Һәммәбез политик тоткыннар идек. Тимер юл кырында күпме мазарат калдырганбыздыр, һәр чокырга унар кешене бергә күмәләр иде. Арада кемнәр генә юк! 1нче Казан дивизиясенең командиры генерал-майор Миронов миңа «земляк!» дип яратып эндәшә иде. «Әйдә, мин сине ике якташ белән таныштырам», – дип алып барды. Аларның берсе – Габидуллин фамилияле профессор, икенчесе кавалерия дивизиясенең баш врачы Валиев Әхмәт дигән кеше булып чыкты... Унсигез яшемнән төрмәгә эләгеп ниләр генә күрмәдем... Шул хәлләргә багышлап шигырь дә яздым:

Качып-посып яшәдек
Сталин заманасында.
Койрыкны кыстык
Бот арасына.
Телне кысып теш арасына,
Ирен арасына –
Брежнев заманасында!
Качтык-постык тау арасына,
Читән арасына.
Андропов заманасында
Күз ачылды, тел ачылды:
Яшик инде иркендә,
Әйтеп калыйк, әйтик,
Языйк, ни теләсәк –
Горбачев заманасында!

Зиннур Таҗиевның шигыре форма ягыннан килеп бетмәсә дә, сүзләре – ачык, эчкерсез, йөрәк түреннән чыккан сүзләр!.. Ул Ибраһим ага исеменә дә озын хат җибәргән, аңа озын гомер теләп калган. Үз исемемә килгән хатлардан тагын икесен телгә алып китәсем килә, иң кызыгы шунда ки, бу капма-каршы фикерле хатлар бер үк көндә килеп төште.

Әлмәттән Галимҗан ага Галимов яза. «Кызганычка каршы, романны укып өлгермәдем, миңа хәзер 74 яшь. Телевизорда Ибраһим кордаш Салаховны күргәч, күңелем әллә нишләп китте. Сез телгә алган Мәхмүт Әбҗәлимов – миңа бик якын таныш кеше. Кулын куеп комсомол билеты тапшырган иде ул миңа. Утызынчы еллар башында мин 40нчы заводның ФЗУсында укыган чагым иде. Аннары Мәхмүт ага ВКП(б) райкомының секретаре булды... Мин 1937 елда кулга алынып коточкыч газаплар кичердем, ул хакта язарга хәзер дә куркам. Җиде ел утырып чыкканнан соң да күрмәгәннәр калмады. 1962 елда гына реабилитацияләндем.»

Роман, Ибраһим аганың радио-телевидениеләрдән чыгышлары кайберәүләрнең «җененә дә кагыла» икән! Бу – табигый хәл! Халикова дип имза салынган хатның адресы-фәләне юк, әмма эчендә язган сүзләре сискәндерә: «Сезнең сүзләрне искә дә аласыбыз килми, Сталин башлы кеше иде, һәркемгә игътибарлы иде, Салахов мулла аны хурлаган. Без Сталин яклы, ул сугышны алып барды. Сез анда юк-бар белән яшьләрне котыртып утырмагыз»...

Ибраһим аганың үзенә килгән хатларның нәни генә бер өлешенә игътибар биреп узыйк әле... Әйткәнебезчә, хатлар күп, хатлар төрле-төрле...

Оренбургтан Тимир Абдуллович Корычов яза.

*«Хөрмәтле Ибраһим абый! Романыгызны укып чыктым. Минем моңарчы дәһшәтле елларда бер гаепсез кешеләрнең төрмә-лагерьларда газап чигүләрен тасвирлаган язмаларны укыганым юк иде. «Тайгак кичү» мине тетрәндерде. Бердән, сез – шул газапларны, җәзалауларны, ачлыктан, суыклыктан кимсетүләрне үзегез татыган кеше... алай гына да түгел! Сез хаксызлыкка чын йөрәктән әрнеп, йөз меңләгән гаепсез кешеләрнең шаһиты буларак намус бурычыгызны үтәгәнсез, дөреслекне безгә, укучыларга җиткергәнсез. Сез язган роман – меңнәрчә палачларны, ерткычларны гаепләү өчен иң кирәкле документаль материал! Сез, Ибраһим абый, бик күп газапларны кичергән хәлдә дә язучылык сәләтен саклап кала алгансыз. Романны язу җиңел булмаганлыгын мин яхшы аңлыйм, сезгә тагын бер кат, яңабаштан, күргән-белгәннәрегезне йөрәк аша үткәрергә туры килгән. Сез бу романыгыз белән алдагы буыннар өчен дә, моңа кадәр яшереп*

*торылган тарихның чын дөреслеген ачуыгыз белән дә ифрат зур хезмәт күрсәттегез.*

*Бу романны тизрәк аерым китап итеп чыгару һәм башка телләргә тәрҗемә итү кирәклеген мин Бөтенсоюз язучылары оешмасының Беренче секретаре иптәш Карповка да хат яздым».*

Афәрин, Тимир ага! Ватан сугышы инвалиды, 1941 елдан КПСС әгъзасы, унбиш тапкыр хөкүмәтебезнең зур бүләкләрен алган кеше, романның кыйммәтен дөп-дөрес аңлаган...

Иптәш Корычов Вл. Карпов исеменә юллаган хатның күчермәсен дә хатына теркәгән. Кылт итеп күңелемә бер сорау инде: укучыларның күпчелеге романны башка телләргә тәрҗемә итүне сорыйлар, киңәшләр бирәләр. Ә шушы эшкә җаваплы Татарстан Язучылары союзы бу эшне юллауның хәселенә кереште микән? Тәнкыйтьчеләребезнең ләм-мим дәшмәвенең бер очы – союзга, аның тәнкыйть секциясенә барып тоташмый микән? Бу хакта да безгә уйланырга кирәк, бик кирәк!

Романның үтә кыйммәтле тагын бер ягын әйтергә кирәк. «Тайгак кичү»дә Ибраһим аганың дәһшәтле юлларында очраган, аның белән соңгы икмәк кыерчыгын бүлешкән, кайгыда юаткан, авырлыгын бүлешеп алган бик күп якты исемнәр халкыбызга кайтты. Вакытсыз дөнья куйган күпме асыл туганнарыбыз китапта яхшы сүз белән яд ителә! Әсәрдә телгә алынган байтак олпат затларның уллары, кызлары өчен нинди олы бүләк булды бу әсәр! Җөмләдән берсе, бүгенге көндә Балтач районы Чутай авылында укытучы Алкин Разит хатларын тыныч кына уку мөмкин түгел. Миңа язган хатында Разит шундый сүзләр яза: «Ибраһим ага – әтиебез Алкин Риаз Йосыф улы белән бергә Сталин төрмәсендә утырган һәм аны соңгы тапкыр күрүчеләрнең берсе буларак, безнең гаилә өчен бик кадерле, изге һәм хөрмәтле кеше. «Тайгак кичү»дә әтиебезнең ихлас чын кеше булуын, намусына хыянәт итмәвен, дөреслек өчен үзен аямыйча көрәшүен бөтен халыкка белдерүе өчен дә без аңа мәңге бурычлы! Ибраһим ага безнең әтиебезнең чын исемен халыкка кайтарды. Дөрес, әниебез бездә кечкенәдән үк әтиебезгә тирән хөрмәт хисләре тәрбияләде. Нинди кимсетүләр, мохтаҗлыклар күрсә дә, әтиебез-

нең: «Балаларны укытырга тырыш!» – дигән васыятен үтәде. Роман басылганда, әниебез Казанда, Резедә апамнарда иде. Ул: «Әни романны җылый-җылый, кат-кат укыды, берничә тапкыр йөрәге кагып тукталып та торды»,– дип сөйләде.

Алкин Риазның балалары Ибраһим ага белән өзлексез багланышта торалар, Балтач районына кайткач, Ибраһим Салахов Чутай авылында була, Алкиннар гаиләсе белән очраша. Разит иптәш Ибраһим ага белән бергә төшкән кадерле фотоларның берничәсен миңа да салган...

Гаиләгә ата кешенең газиз исемен кайтару!.. Моннан да күркәм, моннан да изгерәк эшнең булуы мөмкинме соң?! Аталар төрмәдә эзсез югалса да, аларның күләгәсе ничә еллар дәвамында хатыннарына, балаларына ияреп йөрде. Аналарны эштән кудылар, квартиралардан чыгардылар, балалар үзләре теләгән мәктәпләрдә белем ала алмадылар...

«Романыгызны укып чыктым,– дип яза Казаннан тәнкыйтьче галим Энгель Нигъмәтуллин,– тирән һәм авыр тәэсир калдыра. Рәхмәт. Бик кирәкле теманы күтәрдегез. Үз халкының моңын-зарын, чыдамлыгын, рухи ныклыгын туплаган Яңа шәхес тарих мәйданына килеп басты. Әсәрнең беренче бүлегендә әтиебез Галимҗан Нигъмәти турында да бай мәгълүматлар бар. Белгәнебезчә, аталарыбыз истәлеген мәгълүм елларда ерткычларча кырып ташладылар, яндырырга, юк итәргә тырыштылар. Мин ул чакларда биш-алты яшьлек малай гына идем. Мин әти турында китап язам, һәм һәрбер табылган факт ифрат дәрәҗәдә кыйммәтле булачак. Сезгә үтенечем: әгәр авыр булмаса, мөмкин кадәр Галимҗан Нигъмәти турында белгән-күргәннәрегезне (гомумән беренче очрашудан алып!) язып җибәрә алсагыз, күп рәхмәтләр укыр идем».

Эш-мәшәкатьләре никадәр күп булмасын, Ибраһим ага Энгель Нигъмәтуллинга хатын юллаган. Чөнки – кирәк!.. Кирәк!.. Чөнки авыр юлларда ул очраткан һәр шәхес – бүген тарих, нәкъ менә Энгель әйткәнчә, «халкыбызның чыдамлыгын, рухи ныклыгын, моң-зарын аңларга ярдәм итә торган гали зат».

Куйбышев өлкәсеннән хат язган Әхтәм Әхмәтҗанов иптәш «Тайгак кичү»нең шул ягына да игътибар юнәлткән.

«Халыкның яраткан җырчысы Зифа Басыйрова үзе төрмә юлларына төшмәсә дә, нинди фаҗигале язмышка дучар булган икән! Без караңгы көннәрнең аңа да кагылганын моңарчы бөтенләй белми идек. Романда Чанышев фамилиясе дә телгә алына... Бу кеше генерал Якуб Чанышевның туганыдыр, дип уйлыйм. Димәк, Якуб Чанышевка да байтак кичерергә туры килгәндер. Әнием белән бертуган абыем Якуб ага белән бергә Урта Азиядә басмачыларга каршы көрәшкән. Кая карама, тарихның сукмаклары бергә килеп төйнәлә!»

Әхтәм Әхмәтҗанов яшәгән Теплый Стан авылында «Казан утлары» журналын «уннарча кеше яздырып ала» икән, һәм алар барысы да романны яратып укыганнар. «Тайгак кичү» журнал укучыларны берләштергән, аларны уртаклашып фикер алышырга да чакырган. Күңелле хәл!

«Бәләкәй чакта әбием «хагыннан, нахагыннан үзең сакла» дип, еш кабатлый иде, күрәсең, шушы хәлләр шыпырт кына халык арасында таралган булгандыр... «Сөйләмим – кем белә, ачмыйм – кем күрә»,– ди татар мәкале. Я Раббым, сез язган бу кайгыларны җир ничек күтәрә алган, ничек убылып төшеп китмәгән икән?! Мескен халык нихәл түзгән, көрәксәнәк күтәреп булса да хаклык эзләп ничек чыга алмаган?.. Әтием 1970 елда 60 яшендә вафат булды. Өч сугышта: фин, герман, япон сугышларында катнашып, күп яралар алып кайтты да гомерендә бер генә көн дә ял итә алмады. Әнием белән икесе носилкага салып алып киткәнче эш ташламадылар. Әтием хәтта 9 май Җиңү көнендә дә бер тапкыр да ял итә алмады. Көндез чәчүдә, төнлә – мал карауда. Сугыш юлларының әрнеткеч хәлләрен сөйләштерсә дә, кызганычка каршы, мин аларны язып алмаганмын. Сугыш турында чын дөреслекне сезнең кебек итеп ачып биргән китаплар кайчан язылыр икән? Сезнең китапны укыгач, болай уйладым: сезне, мөгаен генә, шушы көннәр килеп җитеп, чынлыкны халыкка сөйләр өчен язмыш саклап алып калгандыр. Журналны үзебезнең кызларның һәммәсенә укытырга тырышам, чөнки аңлап бетермәүчеләр дә, «кемгә ышанырга да белгән юк» диючеләр дә бар... Мин сезгә мең рәхмәтләр әйтә-әйтә, аякларыгызны кочаклап, гаебем булмаса да гафу үтенеп, үксеп-үксеп җылар идем... «Назло всем смертям, всем чертям»

озак-озак яшәгез! Иң яхшы теләкләр белән Башкортстанның Октябрьск шәһәреннән Нәсимә Галиәхмәтова».

Нәсимә ханымның хатыннан нәни генә бер өзекне сайлап алдым. Ул тормышны танып-белүе, сүзләренең сәнгатьчә яңгырашы белән таң калырлык хат язган. Тормыштан күпне күтә алган укучысы белән очрашу Ибраһим ага өчен дә ифрат күңелле булгандыр, дип уйлыйм...

«Ибраһим ага! Сез язганнарны укып бик күп кешеләр җыладылар, күргән нужаларыгыз турында сөйләшеп, «ничек түзде икән, ничек чыдады?» – диделәр. Киров өлкәсендә яшәүче Хәбибуллин шуны хәбәр иткән. Димәк, анда да романны күпләр укыганнар. Укып, үзләрендә йомылып калмаганнар, уй-фикерләре, кайгы-хәсрәтләре белән бер-берсенә барганнар.

«Мин 1936 елда туганмын, хатыным һәм дүрт балам бар. Бабаебызны – әнкәмнең әтисен – 1937 елда «дини агитация алып бара» дип атканнар, аның кабере дә билгесез. Без «тайгак кичкән вакытта» егылмыйча калган нык ихтыярлы кешеләр белән горурланабыз. Ибраһим абый! Торам-торам да җәмгыятебезнең җилгә каршы барганына һәм суның үргә акканына аптырыйм. Югыйсә әткәй-әнкәйләр безне тел ачканда ук «урлашма!», «алдашма!», «кеше әйберсенә тимә!» дип өйрәттеләр. Ә без алар өйрәткәннең киресен эшлибез. Бу бәлаләрнең башы әнә шул утыз җиденче елларга барып тоташмыймы икән?!» – дип борчылып яза Минзәләдән, Дәвек авылыннан Өлфәт Нуруллин.

Казанлы Рафаил Басыйров хатын русча язган. Мөгаен, ана телен яхшы да белмидер. Барыбер Ибраһим аганың романын бөртекләп укып чыккан, түбәнчелек белән, бик акыллы хат та язып салган. Рафаил Басыйровның әтисе дә озак еллар төрмәләрдә утырып чыккан! «Безнең үткәннәрнең кара сәхифәләрен шундый күңелгә сеңәрлек итеп җиткерә алуыгыз өчен тиңдәшсез зур рәхмәт сезгә,– дип белдерә ул хатында.– Бу роман безнең барыбызны да искәртә: мондый явызлыклар кабатланмасын, дисәк, һәммәбезгә дә уяу булырга кирәк! Әнкәй сөйләгәннәрдән чыгып, әтиемне болай да һәйбәт кеше итеп күз алдыма китерә идем, романыгызны укыгач кына, мин аны тулысынча аңладым».

Аталар белән балалар, буын белән буын тәмам аңлаша ала икән, без киләчәккә ышанычлырак күз белән карый башлыйбыз түгелме?

Килгән хатлардан чыгып тагын бер уем белән уртаклашасым килә. Элегрәк әдипләр, язучылар үзара бик тыгыз аралашканнар. Әсәр язып тәмамлауга дуслары, фикердәшләре янына йөгереп барганнар, берсе язганны икенчесе укыганнар, фикер алышканнар, куанышканнар. Соңгы елларда язучылар үзара таркау гомер кичерәләр, бер-берсенең әсәрләрен басылып чыккач та укымыйлар, көнләшәләр, вак-төяк гайбәтләр тараталар. Кыскасы, әдәбият уңышларына язучылар булып язучылар да куана белмиләр. Борынгы яхшы гадәт кайбер асыл язучыларыбызда сакланып калган икән әле! Мөхтәрәм әдибебез Атилла ага Расих каләмдәше Ибраһим Салаховның романын укыгач аны чын күңеленнән котларга иренмәгән, мең рәхмәт аңа!

«Сине искиткеч роман язуың белән чын күңелдән котлыйм. Бу әсәргә без – укучылар бик мохтаҗ идек. Без гомуми рәвештә репрессияләр турында әйтелгән сүзләрне күп ишеттек, мәгәр моңарчы аны якыннан күреп, аның дәһшәтен сәнгать әсәре аша тоеп, татып караганыбыз юк иде. Менә ул ничек булган икән! Син шушы эре планда үзеңнең гаҗәп оста, һәр ягы килгән әсәреңдә ышандырырлык, төгәл буяулар белән безгә ул тормышның астын-өстен күрсәтә алгансың. Рәхмәт сиңа, дус!»

Менә бу – позиция, менә бу – фикер! Егетлек тә бу!

Роман бүгенгә татар халкы белән бергә яши. Озакламый китап булып басылып чыгар, яңадан-яңа укучыларны үз артыннан ияртер. Рух ирегенә ия булыр өчен, безгә дөньяның дүрт ягын гына түгел, астын-өстен дә бик ачык белергә кирәк әле. Колхозлашу еллары турында да, утызынчы еллардагы ачлык турында да, Гитлерның иң якын дусты Сталинның илне һәлакәткә китерә язган «бөек стратегиясе» хакында да әле бик күп әсәрләр язылыр. Ләкин бер чакта да Ибраһим аганың «Тайгак кичү» романы онытылмас. Татар совет әдәбиятында ул чишмә башы буларак та, үзенең аяусыз дөреслеге белән дә озак-озак елларга кадәр сакланыр.

Балтачка йөз чакрым машина белән бардык. Чепья аша Кунырга барып җиттек. Җәяүле буран уртасыннан төнлә янә Балтачка кайттык. Ике зур очрашу үткәрдек. Ибраһим ага йөзләрчә сорауларга җавап бирде, шигырьләр укыды. Арыгандыр. Арыса да сиздермәде. Куанычыннан балкып, сүзләрен энҗе кебек тезә торды. Озын гомер телик үзебезнең аксакалга!

*1989, гыйнвар*

## Имән чикләвеге[1]

«Имән – киң таралган яфраклы агач, әкрен үсә, әүвәл – сиксән еллар чамасы – буйга тартыла, аннан ныгый, юаная. Көчле, тармак-тармак тамыр җибәрә. Яктылык ярата. 15–60 елдан соң гына чикләвек өлгертә башлый. 4–5 ел саен мул уңыш бирә. Еш кына буе 40–50 метрга җитә. 400 елдан мең елга кадәр яши. Элгәрге Казан тирәсе имәнлекләре тарихка кереп калган. Агачы нык, каты, чыдамлыгы һәм кисентеләрдәге гүзәл рәсемнәре белән адәм улларын гомергә гашыйк иткән».

*Китаплардан алган белешмә*

«Переделкино урманы юлыннан бик ашыгып, каядыр китеп барам. Асфальтта тук, гаҗәп эре, матур имән чикләвеге ята. Әле генә оясыннан чәчрәп чыгып юлга төшкән. Атом бомбаларыннан көчлерәк бу табигать бүләген иелеп алып, куаклар арасына ыргыттым: «Үс әйдә!» Чикләвек «зык» итеп калайга барып төште, консервы савытына. Замана фаҗигасе!.. Мин шул чакта кинәт моңсуландым. Әмирхан ага Еники, Мөхәммәт Мәһдиев иҗаты турында сызланып уйладым, шагыйрьләрдән Мөдәррис Әгъләмов һәм Зөлфәт исемә төште...»

Куен дәфтәреннән. 29 август, 1988 ел

Миңа калса, без әдипләребез турында үткәзеп яза белмибез... Хак! Менә күптән түгел Хәсән Туфан тормышына багышланган саллы күмәк җыентык басылып чыкты. Әйе,

[1] Гыйләҗев А. Имән чикләвеге. [Татар әдәбияты турында уйланулар] // Шәһри Казан.– 1990.– N15.– 28 ноябрь. – Б. 1–3.

кемдер аның күршесендә яшәгән. Кемдер аның белән сәфәр чыккан. Күпләр аның чәчәкләргә гыйшкын абайлаган, икенчеләр шагыйрьнең балаларны яратуына сокланганнар. Хәсән аганың кичергән нужа-хәсрәтләрен әз-мәз санап китүчеләр бар. Еллары тиз-тиз үзгәреп алмашынган, кешелек тарихына коточкыч афәтләр, кайгы, күз яше, кан ташыган, формацияләр алышынган егерменче гасырда сиксән ел гомер кичергән шагыйрь тормышын шушы билгеләмәләр, төче мактаулар, алсу хуплаулар белән генә билгеләп үтсәк – гадел булырбызмы без?

Әллә, җыентыкка өлеш керткән замандашлары мактаганча, Туфанның кылган гамәлләре, иҗат хәзинәсе төче, беркатлы мәдхияләргә сыеп бетәме? Бәс, шулай икән, нигә без бүгенге көн татар халкына Туфанны «сөекле шагыйребез» дип тәкъдим итәбез? Латыш әдипләренә Тукайның юлын-юлга тәрҗемә ителгән шигырьләр мәҗмугасен җибәргәч, шәхси язышуларның берсендә: «Тукайның бөеклеген раслагыз!» дигән үтенеч килде... Гәрчә бу кискен куелган өндәү күңелне тырнап китсә дә, мин әлеге сүзләрдә таләпчән хаклык бар дип саныйм. Тукайның бөеклеген без бүтән милләт вәкилләре дә кабул итәрлек дәрәҗәдә ача алганыбыз юк. Без аның татар тарихында тоткан урынын әлегәчә аңлап та, аңлатып та бетерә алмыйбыз. Тукай – егерменче гасырда татарны милләт буларак саклап калучыларның берсе, беренчесе, милли каһарманыбыз.

Октябрьдән соң Тукай иҗатына борын җыерыбрак караган «кызыл авызлар», соңра аны «юныштырып», башынаягын кыскартып, үз мәнфәгатьләренә яраклаштырдылар. Аларга динсез, денсез, каршылыксыз, шоп-шома Тукай кирәк иде. Һәм андый Тукай торгынлык елларында бик тә ярап торды. Тукайның ислам диненә, дингә кагылышлы рәвештә татар тарихына – мәчет, мәдрәсәләргә мөнәсәбәте әлегәчә ачыкланмаган, ачылып бетмәгән. Бишенче ел революциясеннән соң кайбер руханилар үзләренең искелеккә ябышып ятулары белән шагыйрьнең җен ачуларын чыгарганнар икән, бу әле шагыйрьнең иман юлы түгел.

Гомумән, Җәлил, Туфан иҗатларын да без заманга яраклаштырырга, тарихка шома гына кертеп җибәрергә тыры-

шабыз. Бу ике шагыйребез иҗатына хас уртак бер мәсьәлә бар. Әгәр Җәлил Моабит җәһәннәменә барып төшмәсә, әгәр Туфан озак елларга ерак сөргеннәргә сөрелмәсә... бу әдипләр татар тарихы үсешендә нинди урын алырлар иде икән? Җәлилнең дә, Туфанның да сугышка кадәрге иҗатлары үз чордашларыннан нык аерылып тора идеме? Безнең күп сүзле тәнкыйтьчеләр Җәлилнең сугышка кадәрге шигырьләреннән әллә нинди казанышлар чокып чыгарсалар да, шагыйрь үз чордашлары белән бер дәрәҗәдә диярлек иҗат итте. Җәлил иҗатының сугышка кадәрге чоры үз заманының җимеше дип бәяләнергә тиеш. Туфанның төрмәгә ябылганчы һәм аннан соңгы иҗат үрнәкләре бер чакта да халкыбызның авыр язмышын ачуга хезмәт итмәделәр. Аның беренче шигъри тәҗрибәләрендә ясалмалык, кыланчыклык һәм тәҗрибә хакына гына ясалган үрнәкләр тулып ята. Халык язмышы, аның ачы нужасы, милләтнең киләчәге кыл өстенә куелуы Туфан иҗатында урын ала алмады. Һәм ул күпчелек очракта шагыйрьләр шагыйре, әдәбиятчыларның тәҗрибә урыны булып кала килде. Димәк, төрмә-лагерьлар Җәлил, Туфан иҗатында гаять зур борылыш ясадылар, «Моабит дәфтәре» һәм Туфанның төрмә циклы алар иҗатының таҗы булып калды. Шагыйрьләр иркенлек иҗатында гадәти әдипләр булып калсалар, төрмә кысасы аларны рухи иркенлеккә чыгарды. Бу – шагыйрьләр язмышларын янәшә китергән хәл дә әлегәчә билгеләнмәгән, тулысынча ачыкланмаган. Туфанның төрмә-лагерь юлларын үтеп тә һаман «суллык» кизүеннән аерыла алмавын без һаман читләтеп үтәбез. Буа районына барып кайткач, ул сиксән яшьлек бәлтерәгән бабайның борчак чабуына сокланып шигырь иҗат итте. Әгәр тормыш соңгы чиккә барып терәлмәсә, яшьләр туган җирләрен каһәрләп колхоздан тоташ качмаса, намазлык өстендә изге сүз сөйләп утырасы карт кара тиргә батып борчак чабар идеме? Туфан фаҗига күрмәде, күрә алмады. Андый хаталарны шигъриятттә гомер-гомеренә искиткеч гадел булган, туры сүзле олпат шагыйребез Гамил Афзал да ясаштыргалады. Аның «Тәвәккәл әби» дигән җанлы сурәтләү чаралары белән иҗат ителгән шигырен сәхнәләрдән бик күп «кызыл авызлар» чәчеп йөртте... Әгәр намазлык өстендә иман китереп утырырга тиешле

карчык, нәбәрә-оныгын ияртkән килеш, кара төндә чана тартып, кәҗәсенә печән урларга барган икән, бу – соңгы чик, бу заманның хурлыгы, оятсызлыгы иде бит!..

Төрмә юлларын үткән, ничәмә-ничә ел «лаеш шулпасы эчкән» Туфанның чорыбызның бөек пәйгамбәре Александр Исаевич Солженицынга кизәнүен ни белән аңлатырга?? Ул Солженицынны беренче сулышыннан ук танып алырга тиеш иде ләбаса?! Кызганыч, Туфанның Ленин, Маркслар, матдәләр белән наив мавыгулары да багышланган күмәк җыентыкта уңай ягы дип игълан ителә. Ә ул егерменче гасыр җәбер-җәфаларының, милли каршылыкларның, гарасат-сугышларның тирәнлегендә Маркс-Ленин тәгълиматы ятканын бер чакта да белә алмады. Димәк, әгәр Туфан турында хак сүз әйтеп, халыкка мөрәҗәгать итәбез икән, без аны бөтен каршылыклары, ялгыш-хаталары белән ачарга тиешбез. Әйе, Туфан да, Җәлил дә татарның тарихи үсеш юлында яңача бәя алырлар, бу шәхесләр тарих тәгәрмәченнән төшеп кала торган затлар түгел, алар иҗатында без күреп бетерә алмаган төсмерләр ачылыр, яңа сыйфатлар балкып-ялтырап китәр. Иншалла! Бирсен Ходай!

Күренекле рус тәнкыйтьчесе Игорь Золотусский[1] «Московские новости»[2] атналыгында болай дип язып чыкты: «В самом деле, кто в XX веке спас честь нации? (Сүз рус милләте турында бара! – *А.Г.*) Разве не Платонов[3], не Булгаков[4], не Ахматова[5], не Солженицын? Разве не их мы должны почитать, как почитаем героев, павших на поле боя, как почитаем Андрея Сахарова?»

Империянең тоткасы, таянычы һәм нигезе булган урыс милләте дә XX гасырда саклауга, яклап калуга мохтаҗ. Без –

[1] Игорь Петрович Золотусский (1930) – рус язучысы, әдәбият белгече, тәнкыйтьче.

[2] Көндәлек иҗтимагый-сәяси газета.

[3] Андрей Платонович Платонов (Климентов, 1899–1951) – рус язучысы.

[4] Михаил Афанасьевич Булгаков (1891–1940) – язучы, драматург, театр режиссёры, актёр.

[5] Анна Андреевна Ахматова (1889–1966) – рус язучысы, тәрҗемәче, әдәбият белгече.

татарлар, милләт буларак, астан-өстән, алдан-арттан кысылганда кемнәр кулында калдык та, кемнәр безне яклап сүз әйтә алды?! Менә бүген, афәтле XX гасырның ишеген япканда, без әдипләрнең, рәссамнарның, композиторларның, бүтән тармаклардагы шәхесләрнең эшчәнлегенә гадел бәя биреп, татар халкын саклап калуга, аны яшәтүгә күпме микъдар көч сарыф итүләрен ачыктан-ачык икърар итәргә тиешбез.

Гасыр башында милләтне кемнәр саклап калганын, аларның күпме өлеш керткәнен без бәһали дә алабыз. Алдан искәрткәнебезчә, аларның иң бөеге – ТУКАЙ.

Тукайга милләт көч биргән: шагыйрь белән милләтнең арадашлыгы һич вакытта да өзелмәгән; халык – Тукайны, Тукай татарны аңлаган. Бишенче ел революциясе Тукай белән халкыбызны бер мәйданга чыгарган. Бу гадел революциянең җылысы, Тукайның мәрхәмәте, шәфкатьле кайнарлыгы безнең көннәргәчә җиткән.

Оста алдаулар, буш вәгъдәләр, тарихны бозулар төяп килгән Октябрь революциясе исә татар милләтенә һәлакәт, бетү, инкыйраз әзерләгән. Гаҗәеп талантлы драматург Галиәсгар Камал ачтан үлгән... Рухи бөеклеккә омтылган, халкын да шул югарылыкка өндәгән Такташ, хаксызлык дулкыны дәһшәте астында калып, үз-үзенә кул салган...

Кемнәрдер чор кысасына кереп посканнар, намусларына каршы килеп булса да, Сталин режимына яраклашканнар, партия биргән калыпка сыйган шигырьләрен язганнар, җырларын иҗат иткәннәр. Ленин-Сталинга багышлап, күпме юллар тезгән татар шагыйрьләре! Әле бу ярашу каннан китмәгән: бүген дә, социализм идеяләре чәнчелеп тарих чүплегенә барып төшкәндә дә, безнең әдәбиятта шул тәгълиматка сыену, аңа аркалану, тормышның заман тудырган каршылыкларын Ленин аша аңлату яшәп килә...

Егерменче гасырның кайсы кишәрлегендә әдипләргә яшәү җиңелрәк булган? Гомумән, әдәбиятны үз көчендә яшәтү өчен әдипләргә җиңеллек кирәкме? Торгынлык елларында иҗат итү кыен яки ансат булганмы?.. Үткәннәргә, әдәби үрнәкләргә, мисалларга кайтып карасак, бер төркем каләм ияләренә иң ансат чор – Сталин чоры булган. Сугыш

елларында байтак телләргә хаклык иңгән, сугыштан соңгы елларда да әдипләрнең «язарына азык» мул булган әле. Менә караңгы, сөремле, инде гадиләрдә дә икеле-микеле уйлар уята башлаган торгынлык еллары килеп җиткән. Илне-җирне экономик бөлгенлеккә, экономик һәлакәткә, халыкларны пычакка-пычак китергән, утыз елга якын хакимлек иткән бу еллар, халыкны капма-каршы ике сыйныфка аерган кебек, әдипләрне дә ике төркемгә бүлгән. Берәүләр, режим белән килешә алмыйча, хөкүмәт, партия белән бугазга-бугаз килгәннәр, халыкның күзен ачарга тырышканнар. Аларны төрмәләргә тыкканнар, илдән сөргәннәр, хокуклардан мәхрүм иткәннәр. Кызганычка каршы, татарларда бу төркемгә кушылган әдипләр булмаган, иҗатлары дәвамында режимның кешелексез, мәрхәмәтсез, шәфкатьсез икәнен сиздерепсиздереп алган кыюлар булса да, кешелеген җуйган коммунистлар партиясенә нәфрәт угы җибәрергә берәүнең дә көче җитмәгән. Шул елларда иҗаты чәчәк аткан Әмирхан Еники турында сүз чыкканда, мин мондый фикер әйткәлим: «Әйе, Әмирхан аганың кынысында үткер, булат кылычы бар иде. Ул аны кынысыннан тартып чыгарып, әрәмтамакларның баш очында уйнатмаса да... без кылычның барлыгына ышана идек. «Рәшә»[1]не яза да, кылычның булаттан коелганлыгын раслый, әз генә елтыратып ала... «Саз чәчәге»н[2] язганда кылыч нык ук – яшендәй ялтырап китә. «Әйтелмәгән васыять»не[3] иҗат иткәндә, кылычны инде байлык-муллык мирабына баш орып сукырайганнар да күреп кала! Инде күрмәү мөмкин түгел!

Бүтәннәрнең дә билендә кыны бар иде, кылычларын тартып-тартып та чыгаралар иде... Тик Г. Әпсәләмов, Г. Бәширов кебекләрнең кынысыннан корыч кылыч түгел, озын вә ялганга шомарган тел килеп чыга иде...

Торгынлык еллары кайберәүләр өчен шифалы, рәхәт яшәргә җай биргән уңдырышлы кыр иде. Алар борыннарын җилгә тоттылар: җил кай якка иссә, шул якка борылдылар. Нинди ялган штамплар булмады ул заманда? Мәскәү безгә

---

[1] Ә. Еникинең 1962 елда язылган хикәясе.

[2] Ә. Еникинең 1955 елда язылган әсәре.

[3] Ә. Еникинең 1965 елда язылган хикәясе.

нур биргән... Гәрчә татарның хокукый байлыгын талап, имеп ятса да... Казан биш диңгез портына әйләнгән... Гәрчә татар халкын ярык тагарак янында калдырса да...

Илленче еллар азагында әдәбият мәйданына чыккан яшьләр тиз-тиз үзара аерылдылар. Берәүләр ал зинарны билгә тагып, ике кулны гәләфи чалбар кесәсенә тыгып, күмәкләшеп җырларга тотындылар. Хорда уртак тавыш өстенлек итә, талантың никадәрле куәтле булса да, тавышың аерылмый, тотлыксаң да, хырласаң да, беркем сине ишетми!.. Алтмышынчы еллар дәвамында әдәбиятка килеп кергәннәр дә чор таләбен акламадылар. Әйткәнемчә, татарда диссидентлар, Солженицын, Даниэль[1], Синявский[2], Григоренколарның[3] теләктәшләре, дәвамчылары күренмәде... Һәм шул елларда шигърият мәйданына, кыю-кыю атлап, Мөдәррис Әгъләмов[4] килеп керде.

Аның китап җыентыгына кергән шигырьләре арасында «1962 нче ел» дип тәмамланган әсәрләр бар. Димәк, Мөдәррис Әгъләмов, шагыйрь буларак, алтмышынчы елларда туган икән... Тарихта яхшы сүз белән яд ителәчәк Хрущевның киртәгә барып төртелгән чоры. Җылы ук булмаса да, «җылымса җилләр» искән дәвер... Тиздән әдәбиятта Александр Исаевич Солженицын аваз салачак көннәр. Замандашларымның берсе Солженицын исеме илдән-илгә күчеп йөри башлагач: «Как я его ненавижу!» — дип ычкындырган иде. Дустымның кемлеген мин шул мизгелдә генә аңладым. Александр Исаевич килде дә, әдипнең көче-куәте нинди булырга тиешлеген үз көрәш мисалы белән раслады. Сталин тираниясен Көнбатыш илләрдә озак еллар аңламадылар. Соңра со-

[1] Юрий Маркович Даниэль (1922—1988) (тәхәллүсе — Николай Аржак) — рус язучысы, тәрҗемәче.

[2] Андрей Донатович Синявский (Абрам Терц, 1925—1997) — рус язучысы, әдәбият белгече, тәнкыйтьче.

[3] Григорий Иванович Пидопличко (1927—1973) — рус язучысы, рәссам.

[4] Мөдәррис Зөфәр улы Әгъләметдинов (1946—2006) — шагыйрь, Татарстанның халык шагыйре, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1991), Башкортстанның Ф. Кәрим һәм Татарстан Язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге әдәби премияләр лауреаты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе (1992).

вет чынбарлыгын ачып биргән әсәрләрне, Париждан торып, рус телендә илләргә тараткан шәхесләрнең берсе – Никита Алексеевич Струве[1] болай дип язып чыкты: «А на Западе если и не было повернуто колесо истории, то пришло понимание. Солженицын пронзительно показал то, что некоторые хорошо знали. Но им не верили. Не верили и нам, второму поколению эмигрантов. Вот чудо Солженицына: его слову поверили, потому что это было художественное, нравственное слово».

Сталин чынбарлыгын, ничәмә-ничә еллар буена, дистәләгән кешеләр Көнбатыш җәмәгатьчелегенә җиткерә алмаганнар. Сталин тирәсендә якыннан чуалып, аның «бөеклеге» белән сукырайган Ромен Роллан[2], Эптон Синклер[3], Лион Фейхетвангер[4] сүзе өстенлек иткән. Бары тик әдәби сүз, әхлакый хак сүз яңгырагач кына, Көнбатыш халыклары СССРдагы акны карадан аера башлый. Димәк, иң катлаулы заманнарда да әдипнең хак сүзе ил халыкларының күзен ача ала, фәлсәфәләрендә борылыш ясый.

Татарстанда Солженицынны каһәрләп язучыларның күпчелеге бу борылышны борын җыерып каршылады. Әмма башланган иде инде, «Самиздат» машинкалары өзлексез тукылдады, халык арасында Антонов-Овсеенконың[5] «Портрет тирана», Александр Солженицынның «Раковый корпус» әсәрләре таралды. Алар миңа да килеп иреште.

Язучы белән укучы арасында тыгыз бәйләнеш урнашты.

Мөһим бер мәсьәләгә игътибар итик: Солженицынны никадәр томаларга, фикерен камарга маташсалар да, аның сүзе чикләрне, таш диварларны үтә алды. Ул дөньяда миллион фикердәшен тудырды, һәр сүзе бәрәкәтле туфракка төшә торды, һәм иҗатына булган якты мөнәсәбәт аның иҗади

[1] Никита Алексеевич Струве (1931–2016) – Франциядә яшәгән филолог, тәрҗемәче.

[2] Ромен Роллан (1866–1944) – француз язучысы, җәмәгать эшлеклесе, музыка галиме.

[3] Эптон Бил Синклер (1878–1968) – америка язучысы.

[4] Лион Фейхтвангер (1884–1958) – алман язучысы.

[5] Антон Владимирович Антонов-Овсеенко (1920–2013) – тарихчы, язучы, ГУЛАГ тарихы музее директоры.

гомерен озайтты, пәйгамбәр күңеленнән яңадан-яңа бөек әсәрләр чыга торды. Күңел дулкыннарыңны кабул итә алырлык зирәк халкың, игътибарлы укучыларың булу – әдип өчен иң зур бәхет!

Бүген генә, инде А. И. Солженицынның тарихи миссиясе һәм урыны ачыклангач кына, мин аңа табына башлаган икән, дип уйламагыз. «Иван Денисовичның бер көне» повесте басылгач та, рухлануымның чиге булмады; һәм мин, шатлыгымны уртаклашып, байтак белешләремә, дусларыма хатлар яздым: «Шушы көннән әдәбиятның юлы, халыкларның язмышы үзгәрәчәк!» – дип билгеләдем. Шул хатларымның берсе, ничектер, Язучылар берлегенең партия оешмасына килеп «оялаган». Партоешма архивын бүлмәдән-бүлмәгә күчергәндә, ул «адашкан хатны» үземә Кояш Тимбикова[1] табып кайтарды...

Мөдәррис Әгъләмов яшәгән чорда, аның иҗаты сабыйчак, үсмерчак дәверләрен үткәргәндә, буынга сикергәндә, татар халкының төсе, төсмере нидән гыйбарәт иде? Һәм, гомумән, теге яки бу чорда халыкның төсен, эчке дөньясын, күңел серләрен кем билгели? Әлбәттә, моны бары тик әдәбият кына билгели ала. Тарих белән анык ныгытылган әдәбият кына халыкның чын йөзен ачып сала. Әмирхан Еникинең нәни генә «Матурлык» хикәясе аша без билгеле бер чорда татар кичергән социаль шартларны, төгәл җирлекне тулаем бәяли алабыз. Әдипнең бөеклеге шунда – ул аз сүз ярдәмендә укучының аңына шундый көчле тәэсир итә ки, без укып танышкан чынлыктан котыла алмыйбыз инде. Ә. Еники тасвирлаган чор үз кискенлеге, кырыслыгы, аяныч язмышлары, шулар өстенә тиңдәшсез матурлыгы, чынлыгы, риясызлыгы белән укучы күңеленә сеңеп кала...

[1] Кояш Закир кызы Тимбикова (1937–2004) – язучы, журналист, 1959–1979 елларда «Азат хатын» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире һәм журналның җаваплы сәркатибе; 1979–1982 елларда «Казан утлары» журналының җаваплы сәркатибе. ТАССРның (1976) һәм РСФСРның (1989) атказанган мәдәният хезмәткәре, Х. Ямашев исемендәге премия лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

Ә. Еники үз күзе төбәлгән татар тормышыннан нәкъ менә заманга хас кешеләрне, вакыйгаларны таба белде. «Туган туфрак» хикәясенә килеп кергән татар кызы Кларалар кайчандыр бар иде,— бүген алар юк, алар тарихта күренеп калдылар да югалдылар. Бүген шәһәрдән авылга кайтучы шәһәр туташларының инде теле, гореф-гадәтләре генә түгел, тулаем генофонды да үзгәргән. Чөнки алар – авылдан калага күчкән, шәһәрчә бозылырга өлгергән икенче, өченче буын балалары. Татар торгынлык елларында милли холкын-фигылен тиз алыштыра торган халык булып танылды. Мәсәлән, без милли бәйрәмебез булган Сабан туен ярым-йорты туган телебездә баручы гап-гади спорт ярышларына әйләндердек. Бүтәнчә татарның татарлыгы кайда, нинди сурәттә чагыла? Татар туйларында иннек-кершән битлекләр астына качкан, интернациональ төс алган дәртле апалар, чиный-чиный, «әче-әче!» дип кычкырмыйлармыни? Катнаш туйларны әйткән дә юк, ак яулыкларын татарча җилкәгә салган апалар, Казаннан Әчтерханга ишетелерлек булып «камышлар шаулаганда», «әстәгыфирулла»ларын укып, ишекләргә елышмыйлармыни? Бәбәй ашларында, җеназаларда да татарлар үз телләрен җуя баралар. Кабер ташларын да күпчелек русча сызгалый. Татарның иң кадерле, иң изге җире – Яңа Бистә зираты да шул торгынлык елларында сасы заводлар, сөремле цехлар тоткынлыгында, социализм камалышында калды. Себер татарлары арасында йөргәндә, Кучум хан нәбәрәләре – йомры кара башлы, кара чутыр татар малайларының урам чирәмлегендә «гуси-гуси, га-га-га!» дип уйнауларын күргәч, каным куырылып киткән иде. Авылларга ямь биргән соңгы мәчет манаралары череп ауды, авыллар күчеп китте, зиратлар югалды, татар күкрәге – иркен болыннар черки уйнаган сазламык-су астында калдылар. Татар ана телен онытты, гореф-гадәтләрен ташлады, иманыннан ваз кичте... Шундый заманда – милләт үзенең яшәү көчен, милләт вәкилләренең уртаклыгын, төсен-төсмерен ашыгып-ашыгып җуйганда, татар шагыйре булып мәйданга чыгу җиңелме? Утыз елга якын милли сүлпәнлек елларында татар шагыйре булып калу ансатмы?

Мөдәррис Әгъләмов саз каены кебек як-якка чайкалмады, ул беренче адымнарыннан ук үзенең барыр юлын дөрес билгеләде, ялгышмады. Чөнки ул – табигать баласы. Табигать аның дүрт санын төгәл итеп яраткан, имгәтмичә үстергән, саклаган. Ул үзенә һәм халкына мөрәҗәгать итәрлек үтемле, хак сүзләр сайлады, һәр ымы, һәр ишарәсе белән халык күңеленә үтеп керергә тырышты. Торгынлык еллары юлбашчыларына да, аларның яраннары, ялчыларына әйләнгән әдәби шакалларга да иярмәде...

Сүзенә дәлилләр, фикеренә нигез җитенкерәмәсә, бүгенгене ташлап торып, тарихка борылып кайтты, Бөек Болгар чорына баш иде. Тарихыбыздан көч алды, тарихыбызны ныгытырга үзеннән көч, егәр жәлләмәде. Мисалга шигъри юлларын бер дә китермәм, анысы – галимнәр эше, дип исәпләгән идем. Чөнки авторның күпчелек юллары аның риясызлыгына, намуслы-әхлаклы булуына мисал дип инандым. Алай да бер-ике генә сүз Мөдәррис үзе дә әйтсен әле!

Агачларның төсе алтын сары,
Тик җилбәгәй нарат яшел бары,
Эленеп торды офык читләрендә
Торналарның соңгы тавышлары.
Кемгә кадерле без, кемгә кирәк,
Яшәү серләренә кем өйрәткән?!
...Без һәммәсен алдык табигатьтән.

Бу – чын Мөдәррис Әгъләмов. Табигать баласы булып яратылган, җирдән, күктән дәрт-дәрман алган, Аллаһы Тәгаләдән талант иңгән Мөдәррис Әгъләмов иң кара елларда да үз тавышына хыянәт итмәде, үзе яшәгән чорда татарның җанын ачарга, адашканнарга туры юл күрсәтергә, өметсезләргә кул бирергә, үксезләргә җылы өләшергә омтылды. Утыз ел тоташ аккан язгы ташудай шигърияттән тагын берсен генә мисалга китерим инде. «Хәрәкәт» дип атала ул. Җеназадан соң язылган.

Бозлы яңгыр булып өскә койды кайгы,
Атлау авыр, сөйләү авыр, кием авыр.
Бөтен дөнья үзгәрде күк.
Күзне ачсам –
Шул ук нигез, шул ук урам, шул ук авыл.
Кичә генә кабер казып йөргән ирләр

Мәзәк сөйли, хәмер эчә, курпы чаба...
Елга-елга яшен түккән хатын-кызлар
Гайбәт сөйли, сагыз чәйни, сыер сава.
Бала елый. Көзге арыш борын төртә.
Мал кычкыра. Салмак кына көтү чыкты.
Ялкау гына баш күтәргән моңсу кояш
Пар итте дә күккә алып китте чыкны.
Көндәгечә бөтен дөнья хәрәкәттә,
Тиз җыендым. Калды нигез, калды урам.
Өйгә эшкә, өстәлемә кайту кирәк...
Юл чатында автобусны көтеп торам.

Монда һәр сүз, һәр тәэсирле сүз, йөрәкләргә моң өсти торган һәр манзара – шагыйрьнеке, Мөдәррис Әгъләмовныкы. Бу шигъри юлларда искиткеч зур фаҗига дә, татарга хас эшлекле сабырлык та, яшәү кануннарының аяусызлыгы да ярылып ята. Татар киткән, мәңгелек сукмагына татарны төшергәннәр, аны озатканнар!.. Һәм шагыйрь үзенең чатта басып торуын, үзенең төп урыны шунда икәнен тагын бер тапкыр искәртеп үтә. Әле генә ул:

Юл чатында басып торган
Агач өчен язмыш ачы:
Узганның да, барганның да
Тиеп китәр күчәр башы, –

дигән иде.

Әйе, торгынлык еллары чатында басып торып, егылмыйча калуга да күп көч кирәк иде! Бер яктан баскыннар гаскәре ага. Җиргә туймас генераллар, канга сусап, мадъярларның азатлык хәрәкәтен буып ташлый, Чехословакиягә дөбердәп барып керә. Берлин уртасына, мең вә миллиардларны түгеп, хурлык диварын бастырып куялар. Урыс генералларына җир җитми. Алар Вьетнамга да барып тыкшыналар, Кампучияне басып алалар. Бары тик аларның тузга язмаган идеяләрен куәтләгән өчен генә Фидель Кастроны[1] яклап, чак кына атом бомбалары белән атышып уйнамыйлар!..

Дөньяның әле бер читен, әле икенче кырыен канга батыручы тоталитар режимнарны корал белән, мал белән ныгыта-

[1] Фидель Алехандро Кастро Рус (1926–2016) – Кубаның дәүләт, сәясәт һәм партия эшлеклесе. 1959–2008 елларда – Куба җитәкчесе.

лар. Мозамбик, Ангола, Хәбәшстан, Гыйрак, Ливия лидерларын тәхеттә саклап калыр өчен, совет халкының авызыннан өзеп, миллиардларны исраф итәләр.

Икенче яктан шыпырт кына шовинизм ныгып килә... «Милләтләр бетүгә йөз тота, урманнарда бер төрле генә агачлар үссен, елгаларда бер сорттагы балыклар гына йөзсен! Шул чагында яшәү җиңеләя»,– дип, урыс-татары милләтне бетерергә тотына... Газета-журналлар сәлперәеп кала, татар китапларының саны чикләнә, Рәсәйнең төрле ягына таралган татардан инде бер генә милли каһарман да, язучы-әдип тә, рәссам-композитор да чыкмый башлый. Шул елларда милли төшенкелеккә бирелмәгән, милли аңын саклап кала алган Мөдәррис Әгъләмовны яшьтәшләре чит итмәделәр. Ул чынлыгы, хак сүзе, ихлас моңы белән әлегә әдәбият, сәнгать тирәсендә сакланып кала алган татарлар арасында ныклы урынын тапты. Дөрес, ул Солженицын кебек, торгынлыкка сугыш игълан итмәде, аның иҗатында Платоновча ирония, сарказм да күренмәде. Торгынлык елларына Мөдәррис үзенчә мөнәсәбәт билгеләде: ул татарны татар килеш саклап алып калырга тырышты.

Мөдәррис торгынлык чоры тираннарына дәррәү күтәрелеп чыккан шагыйрь түгел иде. Шуңа күрә ул үзенә остаз итеп, тарих ыгы-зыгыларыннан читтәрәк яшәгән, ак тирмә янына тартылган Х. Туфан, С. Хәкимнәрне сайлады. Бу остазларга фәкать һәлакәткә генә бара торган системаның әҗәле якынлашканын тою насыйп булмады. Риясыз талантка ия булган Сибгат ага Ленинны җырлауга күпме көчен, кадерле вакытын исраф итте...

Андый «нәни, гөнаһсыз» мавыгулар әле Мөдәрристә дә очраштыргалый, ләкин аның штампларын җентекле күз белән укып чыккан иптәшләр шагыйрьнең асла ихласлыгын, мәсләгенең анык икәнен күрерләр, дип ышанам.

Шагыйрьнең соңгырак еллар иҗат җимеше булган «Тукайдан хатлар» поэмасына аерым тукталасым килә. Чөнки бу поэма татар фикри дөньясында аерым бер урын тота, бөек шагыйребезнең эчке дөньясын ача төшә.

Поэма, барыннан да бигрәк, Тукайны аңларга тырышу булып яңгырый. Тукайны аңларга тырышу – үзеңне аның янә-

шәсенә куеп карау, аның җанын талкыган мәсьәләләрне үз аңың, күңел иләгең аша үткәрү дә ул. Кыскасы, Тукай җиләнен үз иңеңә киеп карау! Тукайны тулаем аңламауның зарары турында без инде искәрткән идек. Үз мәнфәгатьләреннән чыгып, Тукайны бозарга маташулар да әдәбиятыбызда шактый зур урын алды. Бик күпләр үз киемнәрен Тукайга киертергә азапландылар. Эш шуңа барып җитте ки, татар меценатлары үз заманының алдынгы вәкилләре булган Акчуриннарны хакәрәт итү эшен дә Тукайга йөкләделәр. Кайбер авторлар милли каһарманыбыз Йосыф Акчураны биргән бу гаиләне ничек кенә таптап үтмиләр! Алар – эчкече исерек баш та, аңгыралар да, эшлексезләр дә... Ә менә «пролетар вәкилләре» иң алдынгы фикер ияләренә әйләнеп, Тукайга «җан азыгы» бирә торучылар булып чыгалар! Акчуриннарның гимназиядә укучы сеңелләре беркатлы ахмак булса, алардагы асрау кыз дөнья бәясе торырлык фикерләр әйтү дәрәҗәсенә ирешкән...

Бүген аермаенча әйтергә кирәк: Мөдәрриснең «Тукайдан хатлар»ы – бөек шагыйребез турында әйтелгән хак сүзләр җыелмасы ул. Җыеп әйткәндә, Мөдәррис Әгъләмов – милли байракны авыр юлларда, караңгы елларда да кулыннан төшермәгән шагыйребез. Ул иҗатын тутыкмас корал итеп, татарларда милли аңны уята килә.

Телебез, денебез сагында торучы бу шагыйрь хакында сүзне шуның белән тәмамларга да булыр иде... Ләкин бер аянычымны тагын уртак итәсем килә. Исегездәме, мин сүземне асфальтта яткан имән чикләвегеннән башлаган идем. Кызганычка каршы, бүгенге тәнкыйть мәкаләләренә караганда, Әмирхан Еники, Мөдәррис Әгъләмов кебекләрнең иҗат казанышларына татарларның шактый битараф икәнлеген күрербез.

«Тукайдан хатлар» поэмасы кергән «Киләчәккә кайту» җыентыгының тиражы – нибарысы 1700 данә генә! 1987 елда – татар уяна башлады дип исәпләнгән заманда чыккан җыентык... Диңгездән бер тамчы! Җиде миллион татарга – мең җиде йөз данә китап! Бу – безнең хурлыгыбыз түгелме соң?!

Татар язмышы авыр заман кичерә. Телебез хәл эчендә. Язмышыбыз кыл өстендә. Татар теле сагында, «чатта», төрле яктан күчәр башлары тиеп киткәндә уяу торучы Мөдәррисне чынлап торып үз арабызга алмасак – йә, кем булабыз инде без?!

Мәрхәмәт, шәфкать тапталганда, дөньяны имансызлар басып киткәндә, аң-зиһен буталып каралганда хак сүзгә тугры калган шагыйрь алда да татар колагына ягымлы сүзләр җиткерер. Тик аның кулыннан гүзәллекне ала белерлек, аның хак сүзен бәяләрлек татар булырмы? Моны өздереп кенә әйтү кыен.

Шагыйрьләргә һичкайчан тыныч заман килмәс. Дөнья сулышын тоеп яшәүче сизгер шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов бу хакыйкатьне бик күптәннән белеп яши. Моны раслау өчен аның китапларын уку да җитә.

## Казан, Казаным!..[1]

Менә ничәмә-ничә көннәр авыр газапланам! Иптәшләр мәркәзебез Казан турында язуымны үтенделәр дә, җиңел кулдан ризалык биреп ташладым.

Ни әйтергә? Ничек әйтергә? Гәрчә хәзерге көндә мәшһүр калабыз турында калын-калын китаплар басылып тора: иketомлык «История Казани»[2] китабы дөнья күрде. Икенче томын укыганда, урыны-урыны белән сүгенеп алырлык моментлар тудырып минем кәефне кырса да, аек күзгә ярап торырлык мәгълүматлар бар. Ләкин минем бүтәннәр үткән эзләрдән, таныш вә күнегелгән сукмаклардан барасым килми. Чөнки һәр татарның үз Казаны! Милләтебезнең иң бөек улларыннан берсе Габдулла Тукай авазы – башкалабызга атап әйтелгән сүзләрнең иң көчлесе, иң гайрәтлесе һәм иң чыныдыр. Кулдан-кулга күчеп йөргән, байтак җәбер-җәфа ашаган егет, Казанга үз мөнәсәбәтен белдерер өчен, сүзләрнең нинди бөекләрен сайлап алган!

Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;
И Казан! дәртле Казан! моңлы Казан! нурлы Казан!
Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.
Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...[3]

---

[1] Мәкалә 1994 елда «Казан» журналының 9–10 санында, 2006 елда «Ватаным Татарстан» газетында (25 август) басылып чыга. «Сайланма әсәрләр»нең 6 т. кертелгән (2016, 27–30 б.).

[2] История Казани: в 2 т.– Казань: Татар. кн. изд-во, 1988.– Т. 1.– 352 с.; Т. 2.– 382 с.

[3] Г. Тукайның 1907 елда язылган «Пар ат» шигыреннән өзек.

Ерак елларга борылып карасак, без Казанның өч дәверен күрәбез: башта ул саф татар шәһәре була, аннары кинәт рус каласына әйләнә, бүгенге көндә ул – катнаш шәһәр. Дөрес, шәһәребез бер милләтне дә тарсынмый, борын-борында монда әрмәннәр яшәгән, чуваш, мари, удмуртлар рәхәтләнеп тормыш итә торган булганнар. Русларга кадәр үк шәһәребез дөньядагы иң зур калалардан саналган, илгәзәк сәйяхлар аны урап үтмәгәннәр, татар җирен аркылы-торкылы йөреп, юлъязмаларында гыйбрәтле хатирәләрне теркәп калдырганнар... Соңра чит чыганакларга татар тарихчыларының эзләнү нәтиҗәләре килеп кушылган, тарихыбызны уңнан да, сулдан да яктыртырга тырышканнар.

Алай да мин шәһәремне бик аз беләм икән. Гомергә аяк басмасам да, мин Париж, Лондон, Берлиннарны яхшырак һәм төплерәк беләм шикелле. Чөнки ул шәһәрләр хакында тау-тау китаплар укылган, кинофильмнар каралган, рәссамнарның йөзләрчә рәсемнәре каршысында уйланып басып торылган. Явыз Ленинның йөз еллыгына кадәр шәһәребезне «чит ил адәмнәренә керергә рөхсәт ителми торган» ябык калалар исемлегендә йөрттеләр. Һәм ул дәһшәтле атама Казанны бик тапкыр тасвирлый иде! Казан гомер-гомергә ябык кала булгандыр кебек тоела иде. Һәм менә миңа, истә-оста югында, үзем байтак еллардан яшәп яткан шәһәр турында сүз әйтү чираты җитте. Җиңел эш түгел, чын тарихыбызны мин бик соңарып, хәтер җепләре чуала башлаган елларда гына таныша-өйрәнә башладым. Күңелнең тере еллары ялган яшәү рәвеше – югары мөнбәрләрдән макталып, дөньяны күмеп киткән чорга туры килде...

Казанга мин сугыш беткән елны, көзлектә университетка укырга дип килдем. Иптәшем Кәрәкәс авылы егете Хәбибрахман Мөхәммәдиевнең аягында чабата иде. Мин кирза итектән, әни әйләндереп теккән солдат бушлатыннан. Университет коридорында беребез – шап-шоп, икенчебез чаж-чож басып, курка-курка гына йөрибез... Ялангачлар, ачлар. Тәҗрибәсезләр. Шулай да Казан тартып китерде, килдек, Казан кешеләре булдык. Хәзер инде олыгаеп бара торган безнең буыннан бер генә дә Казанда туып үскән кешене таба алмассың. Без – авыл кабартмалары. Бер мәҗлестә, дусларның берсенең

кырык еллыгын билгеләп утырганда, аның хатыны мондыйрак сүз әйтте: «Әйдәгез, авылда туып үскән, үз көчләре белән Казанны яулаган ирләребез хакына олы сүзләр әйтик!» — диде.

Хак сүз! Без, төрле җирдә туып, кыен ашый-ашый төрле сукмакларны изеп, шушы ноктага — татар йөрәген һәрчак җилкетеп торган шанлы-шәүкәтле мәркәзебезгә җыелдык. Без 1552 елда бабаларыбыз кулыннан киткән шәһәрне өр-яңадан яулап алырга теләдек. Корал белән түгел, бүтән милләтләрне изепсытып түгел, аң белән, эш-хезмәтебез, рухыбыз белән Казанны тагын татар шәһәре итәргә тотындык. Бу эшнең авырлыгын да, кай тарафларга кадәр илтеп җиткерәсен дә белми идек әле ул чакта. Хәер, без бүген дә «Казан — татар шәһәре, татарның мәгъруур мәркәзе!» дип авыз тутырып әйтә алабызмыни?! Казан — чуар шәһәр, татарлар — чуар милләт. Кайчагында мин, әрнеп-ачынып: «Нигә без шулай тарау? гамьсез? таркау? ваемсыз? кадерсез? хәтерсез?!» — дип кабатлыйм...

Хәтерсез, димәктән...

Хәтерсезлекнең дәвамы нәрсә, дип сорасалар, мин бер сүз белән генә җавап бирер идем: аның дәвамы — битарафлык! Тарихыңа, үткәнеңә битарафлык! Бүгенгеңә, милли хәлеңә битарафлык! Аның да дәвамы — бетү, югалу, инкыйраз...

Әле Бөек Болгар дәүләте шаулап-гөрләп тормыш итеп ятканда, карурманнар, аркылы-торкылы кисешкән чокырчакырлар, көмеш сулы инешләр борылган елгалар ягасына Казан шәһәренә кем килеп нигез салган? Татарларның кайсы төркеменнән булган алар? Тарханнармы, руханилармы, гади җир кешеләреме? Ни уйлаганнар алар? Кичке моңсу учак яктысында бер-берсенә күз текәп ни сөйләшкәннәр? Елларның чуалчык икәнен, һәр ике тарафтан — Көнчыгыштан да, Көнбатыштан да явыз яулар булачагын абайлаганнармы? Бөек Болгарга яу төшкән мәлләрдә халыкның, сөрлегеп, шушы төбәккә, әлегә тын диярлек Казан куенына ябырыласын сизенгәннәрме? Казан болгар-татар өчен өмет учагы, яшәү көче булып яралган. Әгәр шик-шөбһәләре шуңа охшашлы булса, бу шикләр берзаман расланган, Көнчыгыштан яу төшеп, Бөек Болгар шәһәрләре көл вә сөремгә әйләнгәндә, карткоры, бала-чага, хатын-кыз шәһри Казанга ышыкланып җан саклаган. Казан географик урыны, хикмәтле кирмәннәре,

зирәк ил агаларының гамәлләре белән озак-озакка татар-болгар кавеменең төп таянычына әйләнгән.

Булган, тарихтан чын хакыйкатьне алып сөйләсәң, татарда да Олуг затлар булган! Ни аяныч, без аларның исемнәрен, яшәү рәвешләрен, күз тоткан өметләрен, дәүләт нигезен ныгыткан кануннарын, татарны татар итеп, бер йомгак итеп яшәткән дәрт-дәрманының серләрен белмибез. Дүрт йөз илле елга якын тимер кыршау белән уралган аңыбыз үткәнебезнең данлы-шанлы көннәренә барып җитә алмый. Без, коллыкка күнеккән, буе сынган, биле бөгелгән бәндәләр, сирәк-сорак табылган тарихи чыганакларга таянып, үткәннәрдәге бөек шәхесләр хакында бүгеннән торып язарга тотынсак та, канга сеңгән коллык каяндыр бүселеп чыга, безнең гайрәтле, зирәк ханнарыбыз да бүгенге көннең райком секретарьларына охшабрак яралалар. Шуңадырмы безнең бөек тарихыбызны илгә, көнгә, киң җиһанга тапшырып, татарның данын ныгытырга тиешле әсәрләребез әллә кая бара алмыйлар шул. Моңа тарих гаепле түгел, моңа без үзебез гаепле. Үткәндәге бөек чорыбызга тиң тирән акыллы әдипләр кайчан килер татар җиренә?! Һәм килерме әле?!

Русның татарга якты күз белән караган бөек, тиңдәшсез, саф күңелле галимнәре бар. Әлерәк кенә шуларның берсен — Лев Николаевич Гумилёвны[1] — фани дөньядан мәңгелеккә озаттык. Гумилёвның татар милләте язмышы өчен нинди олы гамәлләр башкаруын без әле белмибез дә, бәяләмибез дә. Инде, шөкер, Михаил Худяковны[2] әз-мәз телгә кертә башладык, аның гаять көчле тарихи эшчәнлегенә инанучылар ишәйде. Сталин җәлладлары бу бөек акыл иясен дә аямаганнар... Әмма дөнья йөзендә «татар» дигән милләт яшәгәндә, Михаил Худяковның исеме онытылырга тиеш түгел! Нинди гайрәтле сүзләр әйтеп калдырган ул безгә! Без рус-улакның

---

[1] Лев Николаевич Гумилёв (1912—1992) — рус совет галиме, тарихчы-этнолог, тарих һәм география фәннәре докторы, төрки халыклар белгече, шагыйрь, фарсы теленнән тәрҗемәче.

[2] Михаил Георгиевич Худяков (1894—1936) — рус тарихчысы, археолог, этнограф, фольклорчы. Күп кенә хезмәтләре татар халкы тарихы, Идел буе Болгар дәүләте, Казан археологиясенә багышланган.

наданына ияреп, большевикларга койрык болгап, тарихыбызны тудырган, милләтебезне саклап торган ханнарыбызны аяк астына салып изгәндә, ул болай дия алган: «Большой ум, громадная энергия и колоссальная предприимчивость характеризует личность Улу Мухаммеда[1]... План основания Казанского ханства можно назвать гениальным, потому что хан Мухаммед понял особенность древнего культурного местного населения, и задумавши восстановить мусульманское государство в Среднем Поволжье, правильно оценил шансы на его прочное существование. Дальновидный проект был выполнен с огромным умением, и вновь созданное государство оказалось очень могущественным».

Бу өзекне рус телендә китерүемнең сәбәбе бар: без, татарлар, гомер-гомергә рус командасына буйсынып, «направо!» дигәндә – уңга, «налево!» дип кычкырганда, карышусыз сулга сөрлегә торган халык, үз кешеләребезне, бөекләребезне берчакта да, Худяков атаганча, «большой ум, громадная энергия, колоссальная предприимчивость» дигән эпитетлар белән бүләкләргә күнекмәгән...

Дөрес, Олуг Мөхәммәтнең эшчәнлеген бүтәнчәрәк аңлаткан галимнәр дә бар, әмма миңа, үзем өчен, татар тарихында рус галимнәре дә күккә чөярлек якты шәхесләр булган икән, дип инану рәхәт. Тагын Тукайга кайтыйк... Нинди бөек сүзләр, тиңдәшсез олы хис белән ул татар мәркәзе Казанга үз мөнәсәбәтен белдерә алган... Тукайдан соң күп тә үтмәгән, татарның икенче бөек бер улы – Һади Такташ – Казанны үзенчә күргән, үзенчә кабул иткән:

Казан!
Фахиш шәһәр,
Синең урамыңа
Мин, гыйсъянчы, кереп адаштым.
Череп беткән мещан баткагында

[1] Олуг Мөхәммәт хан яки Олыг Мөхәммәт (1405–1445) – дәүләт эшлеклесе, Алтын Урда (1436 елгача), Кырым (1437) һәм Казан (1438–1445) ханы. Ичкиле Хәсәннең улы. Башка Мөхәммәттән аермалы буларак, Олуг кушаматы ала. Казан ханлыгына (1438), өлешчә Касыйм ханлыгына да нигез салучы.

Иркен уйларымнан саташтым[1].

Шагыйрьләрнең кайсысы хаклы: миңа калса, икесе дә!

«Мухамед-Эмин был очень умным, хитрым и дальновидным политиком»,– дип яза Михаил Худяков. Кызыклы фикер... Казан ханлыгының архивы таланган, урланган, яндырылган. Шушы өзек-өзек фикерләр генә безгә үткәннәребезгә нур юнәлтергә мөмкинлек бирә.

«В этническом отношении основное население Казани было почти однородным. Его составляли потомки булгар. Подтверждением этому являются все виды культуры и ремесла, традиционно связанные с культурой и экономикой Булгарии» дип раслый «История Казани» китабы (1988 елгы басма, 39 б.). Бу фикер байтак еллардан расланып килсә дә, бүгенге чуалчык заманнарда аның әһәмияте аерата зур.

«Литературная газета»ның 1987 елгы 41нче санында рус тарихын өйрәнүгә гомерен багышлаган, күп санлы тарихи романнар язган Дмитрий Балашов[2] мондый нәтиҗәгә килгән иде: «Я не устаю повторять: народ жив, пока жива его историческая память. Кончается память – кончается нация, начинается нечто другое. Так, половцы, покорённые монгольскими племенами, став после этого татарами, удивительно скоро забыли даже свои национальные предания, стали, по существу иным народом».

Карагруһларның тавышын ишетәсезме? Димәк, татарлар – тарихсыз, милли сыйфатларын чәчеп югалткан халык өере икән. Яшәешебезне борынгы Болгардан һәм аннан да элгәре дәверләрдән алып китү – безнең милли горурлыгыбыз барлыгын раслау да ул. Бөек Болгарның ислам динен кабул итү тантаналары бик күп шовинистлар өчен көтелмәгән хәл булды. Без, рустан 100 ел элгәре уртак дин кабул итеп, бердәмлегебезне, дәүләтчелегебезне раслаганбыз икән. Булган татарда акыллы ханнар! Булган Болгарда киң рухлы адәмнәр!

---

[1] Һади Такташның «Казан» драмасыннан шагыйрь Рөстәм монологы.

[2] Дмитрий Михайлович Балашов (1927–2000) – рус совет язучысы, тел белгече.

Болгарда ныгыган тере рух чылбыры өзелми. Казан бик күпләрне үз кочагына алып бергә-бергә яшәтә. Болгар-Биләрләрнең даны-гайрәте Казанга күчә. Әдәби зәвыктан мәхрүм булмаган рус князе Курбский[1] Казан диварларын, йорт-корылмаларын күреп һушсыз кала, соклану сүзләрен язып, безгә ядкяр итеп калдыра. Әби патша[2] да, Казанга килеп киткәч: «Мәскәүдән кала бу – иң зур шәһәр һәм иң матур, төзек шәһәр»,– дип язып калдыра.

Киек казлар, аккошлар, үрдәкләр оя типкән көмеш сулы елга-күлләр белән чолганган Казан... Суларда төрледән-төрле затлы балыклар. Иренмәсәң, уңышын җәлләмәгән киң кыр-басулар. Шәһәрнең дугай-дугай урамнарында меңләгән һөнәрчеләр: тиречеләр, күнчеләр, мәгъдән эретү осталары, корал ясаучылар, сәүдәгәрләр, яугирләр – бае бар, ярлысы да җитәрлек. Күккә ашкан мәчет манаралары, мәдрәсәләр, мәктәпләр. Чибәр егетләре, көяз туташлары белән дә сокландырган Казан! Казан ханлыгы берчакта да күрше халыкларга яу чапмаган. Бары тик рус белән генә бил алышкан. Әле рус өстен чыккан, әле татарлар алар җирен туздырып кайтканнар. Кем хаклы булган да орыш-сугыш кемнән чыккан, бар, эзләп кара хәзер! Дөнья икән, бар да булган! Әмма татарлар күрше халыклар белән дус, тату яшәгәннәр. Моны кабатлап торудан зыян булмас дип исәплим. Бөек Болгар да, аның турыдан-туры варисы шәһри Казан да Идел ягасына сыенган халыкларның уртак санарлык шәһәре, киң күңелле, юмарт мәркәзе булган. Мордваның мәшһүр романчысы Кузьма Абрамов[3] «Пургас»[4] исемле гүзәл романында болгар-мордва мөнәсәбәтләренә хаклы рәвештә дан җырлый.

---

[1] Андрей Михайлович Курбский (1528–1583) – рус полководецы, язучы, тәрҗемәче, меценат, Явыз Иванның ышанычлы кешесе.

[2] Екатерина II Алексеевна Великая (Софья Фредерика Августа Анхгальт-Цербстская, 1729–1796) – 1762–1796 елларда – Россия императрицасы.

[3] Кузьма Григорьевич Абрамов (1914–2008) – язучы. Мордовия Республикасының халык язучысы.

[4] К. Абрамовның 1988 елда язылган романы.

Казан, Казан!.. Ислам диненең, ягъни аң-белемнең йогынтысы көннән-көн көчәя. Берсеннән-берсе матур мәчетләр салына. Кичләрен, шаулап-гөрләп торган базар, ярминкәләр шавын басып, урамнар өстендә моңлы азан тавышы йөзә. Кәрвансарайларда дөньяның бөтен тарафыннан килгән сәүдәгәрләр кайнаша... Елга куентыкларында ханлыкның сәүдә кораблары тукталган. Хәрби кораблар мачтасында хан әләмнәре җилферди. Эшчән халык бәйрәм дә итә белә, бәйрәмнәрнең кадерен ташламый. Күз алдына китерегез: кояшлы аяз көн, Кабан күле тирәсендәге болыннарда меңнәрчә чатырлар корыла, учаклар яна. Дәү-дәү казаннарда, татлы ис таратып, ит пешә.

Арча кыры, Казансу тирәләрендә дә чуп-чуар халык. Арбалар шыгырдый, атлар кешни, колыннар тыпырдап үтеп китә, мал-туарның тояк тавышы күкләргә менеп җитә. Хан бакчаларында аллы-гөлле гонҗәләр тирбәлә, чәчәк түтәлләре арасында, җилпәзә койрыкларын тирбәтеп, тавислар йөри. Нинди агач, ниндәен кош-корт юк ул бакчаларда. Һәркайда, һәр адымда моңлы, сыгылмалы татар сөйләме, татар теле яңгырый. Әтәчләр әлегә татарча кычкыра, сандугач та үзебезчә чут-чут итеп сайрый, яңгырлар да тып-тып итеп татарча тама. Татарча уйлыйлар, татарча сөйләшәләр, татарча аңлашалар, татарча дөньяви эшләрне алып баралар. Беркем үз теленнән тарсынмый, гарьләнми, татар ханнары татарча итеп акча сугалар, дәүләтара килешенүләр дә татарча төзелә. Даруханәләрдә татар утачылары хезмәт күрсәтә. Безнең остазыбыз, тиңдәшсез галимебез Латыйф ага Җәләй[1] аптекарьларны «утачы» дип йөртә иде.

Татар күзе өчен ягымлы манзаралар! Татар колагы өчен сөйкемле тавыш-авазлар! Басып торган җирең – синеке! Баш очындагы күк – синеке! Каеннар да, Идел дулкыннары да, кичке серле шәфәкъ та – һәммәсе синеке, татарныкы! Синең янәшәңдә шул ук рәхәтлекне чуваш, мари да кичерә, башкорт та сиңа кардәш әле, русы да чит түгел, татар түре һәр акыллы затны сыйдыра, яклый, түренә үткәрә. Телең бетәр, хәтерең тапталыр дип куркасы юк, яшә дә яшә генә!..

---

[1] Латыйф Җәләлетдин улы Җәләлетдинов (1894–1966) – тел һәм әдәбият галиме, педагог, профессор.

Булгандыр, ханнарның акылга таманнары да очрагандыр, дуамал ханбикәләр дә җирдә яшәгәндер, кансыз байгуралар да бу дөньяны берәм-берәм ташлап киткәннәрдер. Ләкин ул заман татарныкы булган, данлы-шанлы Казан татарның үзәге, бәгыре булып торган.

Яшьлегем узган Югары Баграж керәшеннәре җәй башында, Яфрак бәйрәме тирәләрендә, күмәкләп серле җырлар җырлый иде, «Чәчәкәй чакларыбыз бар иде» дип, үткәннәрне сагыналар иде. Күршебез инсафлы һәм гаять эшчән Макар дәдәй өч бакалы тальянын үзеннән ерак – тез өстенә үк куеп, гомере буе бер көйне – «Казанны яу алу» көен[1] генә уйнады. Нигә икән? «Чәчәкәй чакларыбыз бар иде» дип, Баграж керәшеннәре кайсы чорларын сагынганнар? Бу җыр нинди җаннар аша үтеп бүгенгегә килеп җиткән?..

Явыз Иван[2] 1552 елның көзендә Казан каласын харап иткән. Бу юлы руслар җиңеп кенә калмаганнар, алар татарны җир өстеннән себереп ташларга карар биргәннәр. Шомлы руханилар патшага хәер-фатиха биреп кенә озатмаганнар, алар да ислам терәге Казанны юк итәргә котыртканнар. Тарихта тиңдәш янәшәлекләр еш очрый. Гитлер[3] да русның үзәге булган Мәскәү, Ленинградларны һәлак итеп, шәһәрләрне җир белән тигезләргә теләгән. Чөнки илләрнең башкалалары – милләтне бер итеп тоткан йодрык та ул, милләткә рух өстәп торучы тереклек чишмәсе дә ул.

Явыз Иван гаскәрләре Казанны алгач ниләр кыланганын соңгы елларда ачыктан-ачык яза башладык. Руслар аскан-кискән, ызаннардан шаулап адәм каны аккан, уйсу җирләргә канлы күлләр җәелгән. Гаскәриләрне генә түгел, хатын-кызны, бала-чаганы да кырганнар, өлкәннәрне дә ая-

---

[1] Татар халык көе.

[2] Иван IV Васильевич (1530–1584) – Мәскәүнең бөек князе (1533), бөтен Россиянең беренче патшасы (1547). 1552 елда Казан ханлыгын басып алган.

[3] Адольф Гитлер (1889–1945) – 1933–1945 елларда – Алмания рейхсканцлеры, 1934–1945 елларда – Алмания фюреры, Икенче бөтендөнья сугышы вакытында – Алмания хәрби көчләренең башкомандующие. Россиядә, Америка һәм Европа дәүләтләрендә Гитлер идеологиясе (нацизм һәм расизм) рәсми рәвештә тыелган.

маганнар. Казан бирешмәгән, Казан кол булырга теләмәгән, ул үлемне коллыктан артыграк күргән. Шул чорның батыр уллары хакында без ни беләбез? Бүгенге катлаулы көннәргә кадәр татар үз исемен саклап килә алган икән, яу көннәрендә арысланнарча сугышкан Кол Шәрифләр[1] рухы, каннан канга күчеп, безне илле итмәгәнмени?! Хыянәтче Камай морзаларга[2] ләгънәт укып, без рухыбызны чыныктырмаганбызмыни?.. Әле моны ачыклаучылар да, ачыкларга тырышучылар да мәйданда юк. Без бик томанлы офыклар артыннан гына Казанны саклаучыларның исемнәрен казып чыгаргалыйбыз. Хәлбуки Казанны саклаганда һәлак булган азамат ирләрнең исемен мәңгеләштерергә күптән вакыт, Казан – татарның мәркәзе икән, егерменче гасырның иң явыз бәндәсе Ленинны үзәк мәйданыбыздан алып ыргытып, аның урынына шәһит киткән бабаларыбызның изге намына пантеон торгызырга күптән вакыт!..

Ханлык җимерелә, тарихи чылбыр өзелә, Казанда татарга урын калмый, аларны еракка, Кабан күлләре артындагы сазлы-батккак урынга куалар һәм, камчы сабы белән төртеп, «Там вам место!» дип акыралар. «Бистә» сүзе шуннан башланып киткән, имеш...

Тарих хөкеме белән Казан көннәрдән бер көнне татар шәһәре булудан туктый... Татар-рус арасында ныклы чик: татарлар Болакның[3] бирге ягына чыга алмыйлар, хокуклары юк. Ике арадагы тартышлар әле озак елларга сузыла. Татарлар әледән-әле рус патшаларына каршы күтәрелеп чыгалар, ирек даулыйлар. Әлбәттә, руслар гел-гел җимерү белән генә шөгыльләнмәгәннәр, бөек милләт вәкилләре арасында җирле халыкның бәхетен-бәхетсезлеген тулаем аңлап яшәгән олуг шәхесләр булган. Руслар шәһәребездә университет ачкан, театрга нигез салган, музейлар булдырган. Гимназияләр,

[1] Казан ханлыгы чорында дәүләт эшлеклесе, дин башлыгы, шагыйрь.

[2] Татар морзасы, Казан аксөякләре арасында Мәскәүгә йөз тоткан вәкилләрнең берсе. 1552 елда Казанны Иван IV гаскәрләре камалышта тотканда, ул дошман ягына чыга.

[3] Казанның Вахитов районында Казансу елгасы белән Түбән Кабанны тоташтыручы канал.

институтлар татар халкы язмышына уңай тәэсир итми калмаган, әлбәттә...

Ләкин ни генә булмасын, еллар татар язмышына никадәрле уңай тәэсирләр китермәсен, Казан бүгенгәчә рус шәһәре булып кала бирә. Татарлар үз тарихларына салкын гына карыйлар, алда әйткәнемчә, битарафлык, ваемсызлык, милли нигилизм көннән-көн киңрәк тарала бара. Бер үк вакытта Казан белән, татар тарихы белән җанлы кызыксыну да арта. Һәркем шанлы-шәүкәтле Казанга үз юлы белән килә, шәһәрне үзе теләгәнчә ача. Тарих, әдәбият бу җәһәттән безнең барыбызга да даими ярдәм итеп торырга тиеш.

Бүгенге татарлар алар гасыр башы вәкилләре түгел инде. Алар – үзгә, бөтенләй бүтән кавем. Аларның сораулары да, кызыксыну мәйданнары да бөтенләй бүтәнчә. Казан, аның тарихы, тарихны тудырган бөек шәхесләре турында заман яңа сүз әйтергә тиеш. Бу сүзне әле мин дә көтәм. Без, әзләпәзләп, Казанны яңадан яулап алдык. Бу мәшһүр шәһәр татарныкы булган хәлдә, дөньяның бөтен вәкилләрен үзенә сыйдырып, аларга тынычлык, рәхәт тормыш, дуслык-туганлык бирсен. Иншалла, шулай булыр да. Татарлар моңарчы сабыр холыклы, эш сөючән һәм кунакчыл халык булып килделәр. Шулай булсын! Шулай яшик!

*1992, 12 сентябрь*

## Рухи яңарыш көткәндә[1]

Бүгенге татар – кичәге татар түгел инде... Татарстан, тезләнеп торган җиреннән калкынып, дөньяга буе барлыгын күрсәтте, ниһаять! Татар бер елдан нинди булыр? Милли аң уянуы, рухи яңарыш аңа күпме еллардан соң килер? Ни дәрәҗәдә? Дүрт йөз елдан артык кол хәлендә яшәргә мәҗбүр ителгән милләт дөнья киңлекләрендә үзенең шанлы-шәүкәтле исемен кайтарырмы?.. Коллык – искиткеч авыр мирас. Мәшһүр Моисей пәйгамбәр[2], Мисырдан яһүдләрне ияр-

[1] Рухи яңарыш көткәндә. Әлеге мәкалә «Ватаным Татарстан» газетасының 2008 елгы 18 гыйнвар санында басыла. «Сайланма әсәрләре»нең 6 т. кертелә (2016, 303–307 б.).

[2] Иудаизм диненә нигез салучы һәм законнар чыгаручы.

теп киткәннән соң, халыкны, туган төякләренә кайтарып җиткергәнче, 40 ел дәвамында чүлләрдә йөртә, коллыкны татыганнарның үлеп бетүен көтә. Шуннан соң гына ирекле адәмнәрне илгә алып кайта... Дөньяның бөтен почмакларына мул таралып, бик тиз үз милли йөзен югалткан татарлардан әнә шундый хурлыклы сыйфатларны кайчанда исә бер бетереп булырмы һәм ничек?! Дөреслекне, гаделлекне, ирек тәмен, горурлыкны онытырга мәҗбүр булган 7 миллион халыкны хәзер нишләтергә?

Милләтнең йөзек кашлары – зыялылар – гасыр башында «Татар йоклый! Уян, татар!» дип иңрәгәннәр. Хәзер Җир шарының бөтен почмакларыннан «Татар уяна!» дигән сүзләр яңгырый. Ышанасы килә, татарның уянуына куанасы килә... Ләкин без бүген кичәге беркатлы татарлар булмыйк инде. Гамьсезлекне, ваемсызлыкны читкә куеп, үз көнебез хакында дөрес фикер йөртергә тырышыйк. Безнең хәлне әллә каян килеп яхшыртмаслар, безнең моңарчы яшеренеп яткан көчләрне өскә чыгарырга форсат барында, үзебезне үзебез тулаем аңлап, милли ресурсларга, милләт маясына дөп-дөрес бәһа куйыйк! Алданмыйк, оттырмыйк.

Милләт уяна, дибез... Әйе, иманнарын югалтканнар иманга килергә омтыла, телсезләре ата-бабаларының газиз телен үзләштерергә тели. Чал сакаллар, сабый нәбәрәләрен җитәкләп, борынгы язуларны белергә теләп, сыйныф бүлмәләренә киләләр. Җирле радиодан татарча эндәшләр яңгырый. Мәчет манараларыннан моңлы азан яңгырап, явызлык хөкем сөргән кара җирләргә нур озата. Таралган татарлар, бик теләп, бер-берсен эзләп табалар. Татар егете беренче очраган рус милләтеннән булган кызга һушы китеп егылмый. Татар кызлары бай милләт егетләренең кочагына атылып тормыйлар. Татар аңы уяна, татар каны яңара... Ләкин ваем булыйк: болар һәммәсе – әлегә тышкы үзгәреш сыйфатлары гына!..

Татарны татар итәр өчен, меңьеллык горур тарихыбызны канына алыр өчен, яңа буыннар кирәк. Коллык белән аңгырайган, коллык белән авырайган хәзерге җәмгыятьтә, хәзерге шартларда милләтнең асыл сыйфатларына ия булган

яңа буын туа аламы?.. Бу хакта, ашыкмыйча, акылны өстен итеп, кат-кат уйларга кирәк.

Яңа буыннар кирәк безгә, татар балалары, милләтне милләт иткән изге сыйфатларга ия булган яңа кеше, яңа татар кирәк. Бу җәһәттән төрле милләт кияүләренең куенына кереп, чит халыкларның токымын яхшырткан, чит милләт балалары белән илне тутырган татар кызларына әр сүзләрен әйтә башладык инде. Хак сүз әйтәбез. Татар кызларының ваемсызлыгы, милли яктан гамьсезлеге илгә мәгълүм: татар туташларының 42 проценты бүтән милләт егетләренең куенында... Милләт язмышын үз кулларына алырлык егет-кыз бәбәйләр бары тик милли гаиләләрдә генә туа, үсә, ныгый ала. «Ана – бөек исем!»[1] – дигән шагыйрь[2]. Без бу мәшһүр юлларны еш-еш кабатласак та, аңа фәлсәфи, дөньяви һәм сәяси бәя биргәнебез юк әле. Хатын-кыз, ана – бөтен матурлыкның, аң-белемнең башлангычы... Бала, ана карынында яралуга ук, дөнья гаме белән яши башлый. Ана аша балага дөньяның бөтен мазалары, бәхет-сәгадәтләре иңә. Баланың ана карынындагы чагы – аның фәрештә вакыты ул! Баланың яшәү рәвешен, телен, иманын иң әүвәл һәм гомерлеккә дип, әнкәсе сеңдерә. Баланың иң сизгер, иң өлгергән чагы – ана карынында. Әле яңа яралган сабыйны аборт белән үтереп ташларга җыеналар икән – сабый шуны сизә, аның нәни йөрәге 220 шәр мәртәбә тибә башлый... Борынгы Кытайда шундый гадәт яшәгән. Бала туарына берничә атна калгач, ата кеше үзенең туачак улы яки кызына, ап-ачык итеп, үз хәләхвәлен сөйләп бирә торган булган. Бер сәгать дәвамында ул сабыена ничек-ничек яшәвен, хатынының барлык сыйфатларын, байлыгын, көнкүрешен, йорт-җире чамасын бәйнә-бәйнә сөйләп биргән. Шундый гаҗәп очраклар булган ки, әтисен тыңлап аңлашканнан соң, сабый туарга теләмәгән, ана организмы аны йотып бетергән... Менә нинди югары аң бар карындагы сабыйларда!

Моннан берничә еллар элек Швейцариянең Гштаад шәһәрендә яшәүче 11 яшьлек кыз Сандра Шварцхаупт дөнья даны

---

[1] Һ. Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасыннан (1927) алынган шигъри юл.

[2] Һади Такташ (1900–1931) турында сүз бара.

алды. Өч октавада да рәхәтләнеп җырлый ала торган иркен, бәллүр тавышлы бу кызның тавышы кебек тавыш дөньяда юк икән. Тиз арада могҗиза булып танылган яшь җырчының сәләте каян килгәнне ачыклаган галимнәр мондый нәтиҗәгә киләләр: авыры биш айлык чагында врачлар ана кешегә күп хәрәкәтләнмәскә, күбрәк ятып торырга кушалар. Ана көннәр буе классик музыканы тыңлап юана. Ана белән бергә карындагы сәләтле бала да музыканы тыңлап, сеңдереп үсә... Бала туган мизгеленнән үк ана белән бергә булырга тиеш, диләр Норвегия галимнәре. Бала туугa, аны әнкәсеннән аермыйлар, йомшак чүпрәк белән сабыйны корыталар да ананың эченә яткыралар. Бала үзлегеннән хәрәкәт итә һәм әнкәсенең татлы күкрәген үзе эзләп таба, имә башлый. Норвегиядә баласын имүдән аерган яки иртә ташлаткан ана юк. Баласы исәйгәнче әнкәсеннән аерылмый...

Без баланы, дөньяга яралуга, казармага куып кертәбез. Сабыйны, дөньяда күренүгә, көчле куллар тотып ала да, урап-чурап, аерым бүлмәгә илтеп ябабыз... Ята ул шунда илереп елап! Совет системасы баланы беренче минутыннан ук коллыкка, буйсынуга әзерли. Яслеләр, балалар бакчалары – шул ук казармалар ич алар! Пионер, комсомол оешмалары, мәктәпләр, төрле түгәрәкләр баланы шул ук кол хәлендә тотмыймыни?..

Шушы җимергеч тегермән ташында вакланган, җаны беренче көннән үк имгәнгән буыннардан милләт язмышын хәл итәрлек асыл ирләр, гүзәл холыклы аналар көтеп буламы? Әгәр бүген татарның уянуын телибез икән, без мәгърифәтебез хакында бөтенләй бүтәнчә уйларга тиеш икәнбез. Милләтнең язмышы – балалар, киләчәк буыннар кулында. Ә бала язмышы – тулысынча аналар, аталар кулында...

Татар баласы иманлы йортта күз ачарга тиеш. Татар баласы ана карынында чакта ук Коръән аятьләрен ишетеп торсын... Бишеге өстендә әнкәсенең нурлы, иманлы йөзе балкысын. Мөнәҗәтләр ишетсен ул, Тукай сүзләрен. Борынгы ханнарыбызның, галимнәребезнең, милли каһарманнарыбызның шанлы исемнәрен ишетеп, шулар хакында китаплар укып, кинолар карап ачылсын аның күзе. Пычрак дуңгыз баласының кыланмышларын карап йокыга китмәсен ин-

де ул. Халкыбызның гүзәл әкиятләре керсен аның төшенә. Уку китапларыннан «поганые татары!» дигән сүзләрне, кара гайбәтләрне укымасын ул... Мәктәпләрдә көне буе «татары, татары!» дигән ләгънәт сүзләрен укып йөргән татар баласында нинди милли горурлык хисе булсын да, нинди милли хисләр уянсын!

Элек милләтнең бишеге – нур бөркелеп торган татар авыллары иде. Хәзерендә авыллар әз калды. Димәк, без Татарстан шәһәрләренә, беренче нәүбәттә шанлы мәркәзебез Казанга, милли төс бирергә тиешбез! Кремль баганаларының тәбәнәкләренә дә ай куеп чыгарга иде... Ирек мәйданы уртасындагы татарны да һәлакәткә илтү юлларын билгеләгән явыз Ленинның һәйкәлен аулак почмакка күчереп, аның урынына 1552 елда Казанны саклап шәһит киткән батырларга искиткеч һәйкәл торгызасы иде. Яңа бистәдәге татар зиратын – Тукай, Сәйдәшләрнең мәңгелеген саклаучы татарларның иң изге почмагын – адәм карарлык тәртипкә китерәсе иде... Азмы бу дөньяда рухи яңарыш, милли уяну кичерергә әзерләнгән милләтнең бурычлары...

Милли яңарышларны кабул итәргә әзер кешеләр булыр, кемнәрдер уяныр, кемнәрдер уянганнарга иярер. Шиксез, нинди кыйналулар күрсә дә, татарның үзәгендә таза күзәнәкләр калгандыр әле. Шифалы еллар татар тамырына да зарури дымны җибәрер... Ә милли рухны, әдәбиятны, сәнгатьне тудыручылар каян, нинди юллар белән көрәш мәйданына килер? Бүгенге әдәбиятка килгән яшьләребез татар теленең моңын, сыгылмалылык серләрен, назиклыгын, кодрәтен белми инде. Журналистлар, дикторлар, күпчелек артистлар «һәм»не «хам»га әйләндереп бетерде. Әби-бабалары әкиятләрне, риваятьләрне, мөнәҗәтләрне сабыйларга сөйләмиләр. Җырчыларыбызда татарның нәфис моңы юк. Яшь композиторлар, өерелеп-өерелеп, Нәҗип Җиһанов сукмагыннан киттеләр. Сәйдәш юлына төшәргә иде!

Казан «Мин – татарның мәркәзе!» дип көлеп торсын. Төрле игъланнарның, урам-тыкрык исемнәренең татарныкы булуын, татарча язылуын сорау – ул гади бер каприз гына түгел, шәһәр урамнары теле – үзенә күрә бер китап ул, белем чишмәсе. «Кызыл билле перәннек» ашасын татар бала-

сы, «Гөлҗиһан» сабыны белән юынсын. Әти-әниләре аңа «Күгәрчен канаты», «Шүрәле бармагы» дигән тәмле конфет ашатсыннар. «Су анасы» дигән тарак белән тарасын ул сачен. Бәйрәмнәрдә кызлар энҗеле калфаклар, бәбәй итәкле күлмәкләр кисеннәр. Чәмчәле читекләрдән кәз-кәз басып йөрсеннәр. Егетләр башында – чигүле кара түбәтәйләр, аякта – гармун кунычлы сафьян итекләр, иңдә – җилбәгәй җибәргән йомшак камзуллар... Болар һәммәсе, бергә укмашып, без көткәннәрне хасил итәрлек милли җирлеккә әйләнерләр.

Әгәр без «Татар уянды!» дип расларга телибез икән, әүвәл башлап сылу кызларыбызга өмет баглыйк: рухи яңарыш ахыр чиктә хатын-кызлар кулында! Татар милләтен уятырлык көчкә ия ир-егетләр, зирәк кызлар алар кулыннан төшәчәк. Хакыйкать бик гади дә, күтәрә алмаслык авыр да...

*1992*

# Хатирәләр

*Гариф Ахунов, Ркаил Зайдулла*

## Как родилась фальшивая легенда?[1]

Жертвами клеветы, моральной несправедливости не раз в истории страны становились лучшие представители интеллигенции, писатели и поэты. Для них, как для офицеров, честь и достоинство значили всегда очень много. Защищая своё достоинство, они готовы были умереть на дуэли с обидчиком… Как же быть с кляузниками, которые продолжают раздирать наше и без того обозлённое на всех и вся общество? Подавать в суд! Вызывать обидчика на дуэль! А если клевета уже пошла гулять по газетам и журналам?!

В прошлом году в октябрьском номере журнала «Казан утлары» увидел свет роман Гурия Тавлина[2] «Катастрофа»[3]. Это наполовину автобиографическое произведение. Автор романа в начале 50-х годов был узником ГУЛАГа, после освобождения многие годы оставался в стороне от литературной жизни.

Думаем, читателям известно о том, что вскоре после войны «отец народов» Сталин начал новую волну репрессий: вновь стали арестовывать тех, кто уже отсидел, началась борьба с «космополитами», врачами-«отравителями», искореняли малейшее инакомыслие. «Всевидящее око» не обошло тогда вниманием и студенчество, особенно тех,

[1] Әлеге мәкалә «Вечерняя Казань» газетасының 1992 елгы 14 октябрь санында басыла. «Сайланма әсәрләр»нең 6 т. кертелгән (2016, 677–680 б.).

[2] Гурий Иванович Тавлин (1925–1998).

[3] Г. Тавлинның 1996, 2007 елларда чыккан романы.

которые проявили себя мыслящими, творчески настроенными личностями. В 1950-м в Казани были арестованы студенты: педагогического института – Гурий Тавлин, университета – Мазит Рафиков[1] и Аяз Гилязов.

Все они были молоды, но Тавлин и Рафиков уже прошли фронтовые дороги, участвовали в Великой войне, Гилязов же до того, как стать студентом, был колхозником и комсомольским работником. Разместили их в отдельных камерах следственного изолятора, и каждый задавал себе вопрос: «за что меня арестовали? Если по доносу, то кто это сделал, что обо мне написал?»

Автор романа «Катастрофа» дал свой ответ на этот вопрос, который тут же вызвал резонанс у «доброжелателей».

Вот отрывок из заметки критика Мансура Валеева[2]: «И писателя Мазита Рафикова, и автора романа Гурия Тавлина предал один человек. В произведении его имя приводится как Риан. Думаю, что внимательно прочитавшие роман с лёгкостью узнали этого типа. Речь идёт о ныне живущем и достигшем самых высоких рангов писателе. Коли теперь стали известны такие вещи, как мы должны оценивать всё написанное этим писателем?»

Нетрудно понять, на кого пало это непомерно тяжкое обвинение. Репрессированы были трое: по Тавлину и тем, кто поспешил ему поверить, получается, что Мазита Рафикова и Гурия Тавлина предал третий арестованный. Критик напомнил, что в произведении он носит имя Риан, а ведь это был писательский псевдоним Аяза Гилязова в молодые годы. Более того, ни Рафиков, ни Тавлин не достигли «самых высоких рангов», а Гилязов – лауреат премий РСФСР и ТАССР по литературе, заслуженный деятель искусств РСФСР и ТАССР...

Короче говоря, обвинительный акт был жестоким и категоричным. Критик взял на себя несвойственную этой профессии роль прокурора, и то, что автор романа выдви-

---

[1] Мәҗит Мәгъсүм улы Рәфыйков (1925–1986).

[2] Шәһри Казан.– 1991.– 21 ноябрь.

нул в качестве версии, предположения, утвердил в качестве приговора. Он решил не прибегать к детальному ознакомлению с сохранившимися следственными материалами тех лет, чтобы попытаться ответить на вопрос по существу, а не на основе эмоций. Цель была достигнута – легкоранимый писатель забыл о своих творческих планах; его жена, трое взрослых сыновей, их семьи потеряли покой...

Аяз Гилязов обратился с просьбой восстановить справедливость не в суд, не в прокуратуру, а в правление Союза писателей Татарстана. Выяснение обстоятельств этого непростого дела было поручено известному критику Рафаэлю Мустафину. Мустафин ознакомился с материалами следственных дел в архиве КГБ республики и, выступив на правлении Союза писателей, заявил, что у него нет оснований сомневаться в честности и порядочности Аяза Гилязова: он не писал доносов. Гилязов успокоился, стал вновь обдумывать план большого романа. Но не тут-то было!..

30 мая 1992 года та же газета «Шәһри Казан» опубликовала памфлет «Власть ненасытных» Джавад-ага Тарджеманова[1], снискавшего известность благодаря «разоблачениям» других писателей. В памфлете приводится цитата из статьи М. Валеева, подчёркивается, что творческая деятельность Аяза Гилязова непомерно преувеличивается. Тарджеманов не заметил или не захотел заметить, что Р. Мустафин пришёл к совсем иному выводу. Да и ему самому никто не препятствовал всё проверить, прежде чем выступить с публичной клеветой, ссылаясь на аннотацию М. Валеева.

Эти обстоятельства заставили нас, авторов этих строк, ещё раз взяться за поиск истины. Говоря «заставили», мы делаем это решительно, потому что повторное обвинение известного писателя и общественного деятеля Аяза Гилязова вызвало растерянность у многих наших товарищей по перу – и пожилых, и молодых. Заручившись письмами Союза писателей Татарстана, мы отправились в КГБ республики. Там нам предложили ознакомиться с весьма объёмистым делом под номером 25 374. Книга размером с большой роман. Допросы, ответы, заявления, апелляции. Есть написанные от

[1] Җәвад Әфтах улы Тәрҗеманов (1920–1995).

руки, есть отпечатанные на машинке. Стоят подписи и Аяза Гилязова, и Мазита Рафикова, знакомые почерки...

Несколько часов мы читали старые материалы, ужасаясь человеческой трагедии тех лет.

Вот следственное дело о Мазите Рафикове. Он уже умер. Его жизнь вряд ли можно назвать счастливой. Воевал, был ранен, награждён медалью «За победу над Германией». Затем учился – сначала в пединституте в Уфе, потом перевёлся в Казанский университет. Вместе с Гилязовым был в студенческом творческом клубе «Зелёная лампа», созданном в ту пору на историко-филологическом факультете. При самом большом воображении «Зелёная лампа» на контрреволюционную организацию не тянула.

Арестовали всех троих почти одновременно: Тавлина раньше на несколько месяцев, затем, 23 марта 1950 года – Гилязова, а 31 марта того же года – Рафикова. В «делах» – протоколы допросов всех троих. Из них видно, что Гилязов только подтвердил то, что до него говорили двое других. В обвинительных заключениях на Рафикова Гилязов не фигурировал; в обвинительном заключении, которое предъявил Гилязову 5 апреля 1950 года капитан Горшенин[1], говорилось, что он был связан с «антисоветски настроенными лицами: Ландыш[2], Тавлиным, Кузнецовым[3], с которыми в 1946 году среди населения Заинского района, а также студентов г. Казани проводил антисоветскую агитацию».

Теперь, в доказательство сказанного, несколько выдержек из протоколов допросов. (Мы не хотим как-либо осудить уже в своё время безвинно осуждённых, а лишь справедливости ради...)

24 января 1950 года Гурий Иванович Тавлин на допросе сообщал: «В июне 1946 г. демобилизовался и приехал в деревню, где познакомился с Гилязовым. Вначале взглядов

[1] МГБ хезмәткәре.

[2] Габдрахман Гатаулла улы Ландыш (1903–1950) – укытучы. 1950 елда кулга алынып, 10 елга ирегеннән мәхрүм ителә. Җитәрлек дәлилләр булмау сәбәпле, 1956 елда чыгарыла.

[3] Александр Маркелович Кузнецов – А. Гыйләҗевнең яшьлек елларындагы «Бөек» дусты.

Гилязова я не поддерживал, а затем, попав под его влияние, постепенно стал разделять его... высказывания: клевету на колхозную действительность и др.»

Заметим, что Гилязов ещё не был арестован, но на него собирали компромат... Удивительно и то, что прошедший огни и воды фронтовик так быстро попал под «политическое влияние» ничего, кроме своей деревни, не видевшего юнца.

17 мая 1950 года Рафиков на допросе характеризовал Гилязова как человека, настроенного против властей, говорил, что и он разделял его критические высказывания о колхозной и советской действительности. Затем Рафиков вспомнил, как 13 ноября 1949 года, после студенческой вечеринки, он вместе с Гилязовым гулял по улицам Казани и рассказал своему товарищу легенду о ханском сыне. Хан подарил сыну стрелу с золотым наконечником и завещал всегда держать лук на плече, а стрелы в колчане. Но сын хана забыл завет отца, и лук со стрелами сгнили без употребления. Отсюда вывод: лук и стрелы – для того, чтобы разить противника, об этом нужно всегда помнить. Этот противник – власть имущие... И точный выстрел можно сделать только тогда, когда у тебя есть сила в руках.

Гилязов же в своих показаниях так характеризовал Рафикова: «За время нашего знакомства он вёл себя как подлинный патриот Родины...»

Когда мы перелистывали эти пожелтевшие страницы, было грустно и тоскливо: сколько судеб перемолото и разрушено в гигантской мясорубке! Искать сегодня среди тех, кто прошёл через лагеря, тюрьмы, ссылки, кто испытал адские страдания, но случайно остался жив, искать среди них виновного – занятие непристойное.

У каждого честного писателя душа болит, когда в газетах и журналах появляется клевета, больно бьющая по незаживающим ранам много переживших людей. Покаяние, жизнь без лжи и оговоров – этому нужно научиться, и это нам ещё предстоит...

*1992*

*Шамил Рәкыйпов*[1]

# Юлбарыслар шундый булсын!

*(Радиочыгыш)*

Халкыбыз, ошбу бала дөньялыкта изгелек кылсын, кешелекле булсын дип, сабыйларга Габдулла, Галимҗан, Гарифҗан, Мөхәммәт, Нурихан, Аяз, Саҗидә, Ләбибә, Шаһидә һ.б. шундый затлы исемнәр кушкан.

Юраганнары юш килгән аларның. Исеме – җисеменә юш килгәнлеген исбатлап, күбесенчә Аяз турында булыр минем бүгенге хикәятем. Моның җитди сәбәбе бар: Аяз Гыйләҗевкә 70 яшь тулды! Ул моңлы-көйле Сарман якларында укытучы гаиләсендә туган. Зәй төбәгендә яхшылыкны күреп үскән, төрле җирдә белем алган, тормышның ачысын-төчесен татып, хезмәттә чыныккан. Шулай, заман зилзиләләренә бирешмичә, төрле һөнәрләр үзләштергән чын ир булып җитешкән. Нәтиҗәдә, тирән мәгълүматлы булу, кешелекле кешеләр белән даими аралашуы аркасында хакыйкатьне, гаделлекне үзенә гомерлек маяк итеп, рияланмыйча туры ярып әйтергә күнеккән безнең хөрмәтле юбилярыбыз.

Аның бүгенге төп байлыгы – бердәм, тату, уңган гаиләсе. Һәм, әлбәттә инде, халкыбызның моң-зарын, кайгы-хәсрәтен, юлбарыстай көчлелеген (ул юлбарыс елында туган[2]), хәтәр кимчелекле якларын һәм алардан арыну зарурлыгын оста итеп тасвирлаган ИСКЕРМӘС әсәрләре!

Аязны мин 40 елдан артык beләм инде. «Татарстан яшьләре» газетасы таныштырды безне. Шунда минем «Чуен багана» дигән комедиям укып тикшереләчәген белеп килгән иде ул. Түгәрәкне шагыйрь Шәрәф Мөдәррис җитәкли иде. Аяз игътибар белән тыңлап утырды, ахырдан чыгыш ясады. Уңай һәм җитешмәгән якларны күрсәтте.

Бер-беребез белән якыннан таныштык без бу кичтә: мин трампаркта моторист булып эшлим. Аз түлиләр, Аязның да хәле хөрти, фатир түгел, язарга өстәлебез дә юк. Эзли тор-

[1] Шамил Рәкыйповның радиодан чыгышы. 4 апрель, 1998 ел.

[2] Юлбарыс белән Аждаһа – бер ел исеме микән? Аяз үзен, Аждаһа елында тудым, дип саный иде.– *Н. Гыйләҗева искәрмәсе.*

гач, икебез дә буйдак булгач, якыннан гына – Островский урамыннан – баш тыгар урын таптык. Улы белән хуҗабикә түр якта, без – ишек катында, көн яктысы төшәргә тәрәзә дә юк. Безнең аркылы үтеп-сүтеп йөриләр. Су, газ, ванна, җылы бәдрәф дигән нәрсәләр төшкә дә керми безнең. Суларга һавасы да җитми – төнлә шырпы сызсаң, ул да сүнә.

Барыбер күңел көр. Ичмаса, фатир өчен түләргә җиңелрәк булыр дип, мөхәррире Рафак Тимергалин булган газетабыз оештырган «Җиңел кавалерия» рейдларына йөрибез һәм тәнкыйть мәкаләләре бастырабыз. Төн – безнеке. Пегас дигән канатлы тулпарда хозурланабыз. Аяз, бу җәһәттән иярдә нык утырганлыктан, ат эчергәндәгечә сызгыра-сызгыра, ботарлапмы ботарлый минем сәхнә тамашаларын. Аннары – лекция. Ни генә әйтмә, 1948 елда ук ул «Ян учагым, ян!» дигән лирик хикәя бастырып чыгарган кеше ич! Белеме дә – тәмамланмаган университет. Хикәя, парча яза, фельетонга да теше үтә. Ә икешәр-өчәр кат «сөрелгән» драмалары – өстәлнең яртысында бер өем. Аның егәрлегенә, вакытны дөрес итеп бүлә белүенә, күргән бәләкәй генә очрактан фәлсәфә чыгарып вакыйга ясый алуына шаклар катам. Бик тиз араларда газета-журналларда егермеләп хикәя, фельетон бастырып чыгарды. Яза башлаган «Җиз кыңгырау»га тотынса, таң атканын да сизми.

Аның беренче китабы – «Рәтле кешеләр» – 1959 елда басылды. 1960 елда «Яшьлек юлларында» китабына ябырылды. Аннары «Дүртәү» повесте өлгерде. Монысы «Мәктәп китапханәсе» сериясендә балаларга гына тәгаенләнсә дә, әдәбият сөючеләр һәммәсе шашып укыды аны. Чөнки бу әсәр, тыйнак кына итеп, хикәя дип аталуына карамастан, повестька тартым иде. Әүвәлгечә, халыкчан образлар, аларның җор теле, кешенең катлаулы рухи дөньясы һәм авторга хас кырыс реализм үзенә җәлеп итте. Тоемлавыбыз, әсәрне ошатып башкаларга да сөйләвебез тикмәгә генә булмаган: авторны шул елда ук СССР Язучылар Союзына алдылар.

Уңганлыкны вакытында күреп бәяли белү могҗизалар тудыра. Аяз татар прозасын берсеннән-берсе кызыклы, үткен сюжетлы, заманыбыз чынбарлыгын гуманистик идея-эстетик таләпләр югарылыгында гәүдәләндергән соклангыч по-

вестьлар белән баетты. Романнарга тотынырга да кыюлыгы җитте. Һәм алар да киң җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнде. Ә драматургиясе белән бөтен илгә танылды: иң шәп пьесалары авар, башкорт, чуваш милли театрларында, рус театры сәхнәләрендә уңыш белән барды. «Югалган көн» драмасы чит илдә словак телендә дөнья күрде. Рус теленә тәрҗемә ителеп басылган пьесалары да байтак аның.

Шулай итеп, әдәбиятны һәм театр сәнгатен үстерүдәге фидакяр хезмәтләре тиешенчә бәяләнде: А. Гыйләҗевкә 1978 елда – Татарстанның, аннары 1985 елда Рәсәйнең атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде. Ә шушы куанычлы еллар арасында – 1983 елда – ул җөмһүриятебезнең Г. Тукай исемендәге премиясенә лаек булды. Күңел күзебез яктырып, мәрхәмәтле кояш тагын да матуррак балкый кебек тоелды. Хәтеремдә: шәрәфле указ басылган газеталар әле таралырга өлгермәгән иртәдә мин, ике данәне эләктереп, Займищега очтым. Дачада ял итүче халык әле уянмаган. Юбиляр өенең өстәге «күгәрчен оясында» идән шыгырдый. Бу – Аяз. Төп ишек бикле. Ә шыгырдау дәвам итә. Аяз йокламаган... Шартлы морзе алифбасы: бер һәм бер. Өч тапкыр. Баскычтан, дөбердәп, Аяз төшә. Аңа котлау сүзе әйтеп газеталарны төртәм. Ул, кочаклап, мине өскә сөйри... Шомырттай кара күзле чибәр яшь ханым Нәкыя ихлас елмая. Гомумән, каләмдәшемнең иҗади уңышларында аның өлеше дә бар бит. Әдибебез турында күбебез сокланырлык кайгыртучанлык күрсәтеп, тормыш көйсезләнгән чакта, күңел күгендәге төшенкелек болытларын куып, илһам, кайнар дәрт бирүче шушы кара күз, илаһи зат – Нәкыя ханым иде бит!

Болары – лирик чигенеш. Әмма тормыш, Аяз үзе сурәтләгәнчә, гаять дәрәҗәдә күпкырлы бит. Ул тәүге китабын юкка гына «Рәтле кешеләр» дип атамаган: димәк, мин аның үзен дә чын-чынлап рәтле кеше икәнлеген ныклап расларга тиешмен.

Хәзер янәдән Шура апа фатирының без ишек катында яшәп иҗат иткән көннәргә чигенү зарурдыр...

Берзаман Аяз өйгә балкып кайтып керде. Аның «Киек Каз Юлы»н театрда укып, артистлар «әйбәт» дип бәяләгәннәр икән. «Әйдәле, истә калырлык итеп билгеләп үтик әле мон-

дый зур вакыйганы!» – ди Аяз, мине ашыктыра. Кольцода бүтәннәр көтеп торалардыр, ахры, дим эчтән генә. Шунда таба юлыбыз. Юк, университетка таба менеп киттек. Көлә бу. Ак колонналарны узып, урамның икенче ягына чыктык та, сырлап ясалган авыр ишекне ачты да Аяз: «Мисыр падишаһларының берсе зәвык белән салынган бик әйбәт бинаның ишеге өстенә: «Җан дәвасы» дип язылган. Безнең бу белем сарае да шундый!» – диде. Һәм китте сөйләп, китте сөйләп...

Безне Әбүгалисина гыйлем эстәргә кергән тылсымлы серле җир асты куышына охшаган, гаҗәеп матур бизәкле диварыннан, биек гөмбәзеннән гөлләр салынып төшкән соклангыч мәгарәдә без яраткан артист Вәкил Закиров каршылады. Култык астына китаплар кыстырган. Артист кулындагы китаплар – Аяз үтенүе буенча миңа укыр өчен алынган Шекспир, Ибсен, Шоу, Чехов әсәрләре иде. Чәйләп-мәйләп алгач, Вәкил куен кесәсеннән тоткалы көмеш кәсә чыгарды. Мин аны һаман саклыйм. Аяз алтын каләм бүләк итте: минем туган көнне каршылаганбыз икән! Матур-матур теләкләр әйтелгәч, минем «Чуен багана», «Арзан матурлык» һәм «Сөю билгесе» дигән бәләкәй комедияләрне ничек төзәтүләрем белән бик кызыксындылар. Вәкил хәтта, кайбер мезансценаларны көчәйтә төшү өчен, уйнап та күрсәтте. Тәгәри-тәгәри көлдек, һәм мин бу күренешне «мыекка бөтердем».

Бер-бер артлы көннәр, айлар үтә тора. Аяз «Чаян» журналына әдәби хезмәткәр булып урнашты һәм төннәрен фәкать үз иҗатына багышлады. Аңа карап мин дә үҗәтләнә төшәм. Әллә күңелне күтәрер өчен инде, ошаткалый бу минем кайбер мәзәк-күренешләрне. Кыскасы, тәвәккәлләп, өч комедиямне конкурска дип почтага илтеп томырдым.

Соңгы вакытта авырып та йөргәнгә, азрак ял итәргә иде исәп. Ләкин бу тәтемәде: мәҗбүри «озын сәфәрен» тәмамлап, Хәсән ага Туфан кайта икән. Аны каршыларга дип, яшьләрне оештырыр өчен, вузларга, тулай торакларга чаптык.

Җәйге ял вакыты булып, кайсы-кая таралган чак идеме, әллә Аяз фараз кылганча, өстән белдереп җиткергәннәрме, шагыйрьне каршыларга килүче каләм әһелләре күп түгел иде. Аяз, «Миңлекамал» – монысы, Бу – «Тукай турында поэмалар», монысы – «Йөзек кашы», монысы – «Дустым Ман-

сур», тегесе – «Дүрт елга буйлап»... Әнә янында яңа шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов, бөтерелгәне – Уфа кунагы Мостай ага Кәрим һәм райондашың Зәки абыең[1]», – диде дә мине шул төркемгә таба тартты.

Вагоннан төшүгә, чал чәчле, ябык чырайлы шагыйрьне урап алдылар. Кайсы аркасыннан сөя, кайсы кочаклый, үбә...

Җиңел машинага чаклы озаткач, мин, авыр сулап, шагыйрь язмышы турында уйлана-уйлана, кайтып киттем.

Аяз соңгарды. Ул, керә-керешкә: «Старик, борыныңны салындырма. Бие, давай! Ну, чәй дә ярый. Авыз кипте, җеп өзәрлек хәл калмады», – диде һәм үзе бик хөрмәт иткән шагыйрь Салих Батталны очратуын сөйләде. Аның нинди әсәрләрен укуымны сораШты.

– Аз, бик аз! – диде Аяз. – Баттал – гражданин шагыйрь генә түгел, иң кәттә, иң үҗәт, иң гадел көрәшче дә ул! Аның без туган елларда ук язган «Организатор» исемле комедиясен дә укымагансың инде, кәнишне?..

– Юк шул, белмим...

– Белерсең! Менә шул мишәр абзаң теге конкурсның башлыгы икән бит. Синең турыңда сорашты. «Кәлҗемәләреңне» укыган. Кыҗрама, тотын урындыкка, ошаткан ул аларны, парин! Беренче премияне бирәчәкбез, ди. Яса чәеңне куян каны төсле итеп... Юзәйнең «Таныш моңнар»ын да ошаткан. Тоже беренче премия!..

Алдык без ул бүләкләрне. Бардык Мәскәүгә яшьләрнең Бөтендөнья фестивален ә, «Лауреат» дигән медальләрне ялтыратып. Фестивальдән кайткач, аякларны көчкә сөйрәп йөри башладым. Аяз бу хәлгә тиз игътибар итте. Туйда, әйе, Нәкыя–Аяз туе шул ук фатирда гөрләп узды бит. Олы Юзәйнең арыслан ялыдай озын чәчләрен тузгый-тузгый биюе һаман күз алдымда. Вәкил дә сикереп төшәргә хәзерләнгәндәй, почмакка сөялеп, елмаеп тора... Аязның энесе Алмаз баянда сиптерә...

Туй мәшхәбәләре узуга, Аяз табибә апасы – Ләйсән белән киңәшеп, аның галимә-остазы Алимә Кутуевадан мине кара-

---

[1] Зәки Шәрәфетдин улы Нуретдинов (Зәки Нури, 1921–1984) – татар шагыйре, публицист.

вын үтенгән. Бардым мин бу апа хозурына: күкрәкне, арканы кат-кат тыңлагач, ябык гәүдәмә карап, борчылып:

– Хәлең бик үк мактарлык түгел, балакай,– диде ул.– Операция кирәк булмагае.– Һәм тормыш шартларым, кайчан, кайларда эшләвем белән кызыксынды.

Мин дөресен сөйләдем. Сүземне түгәрәкләп, «Татарстан яшьләре» газетасында эшләвемне әйттем. Ул, моңсу гына елмаеп: «Аделша абыең кебек икәнсең. Сугыштан кайта алмады. Ул да бик каты салкын тидергән булган... Шагыйрь Гадел Кутуйны беләсеңдер бит?» – диде.

– Бик беләм. Аның «Сагыну» нәсерен, «Тапшырылмаган хатлар»ын бигрәк тә яратам. Үлеп яратам. Үзем дә шундый «Барып аласы хат»ны язам хәзерендә.

– Алайса, үлмә әле, балакай. Ә без сине Газраилдән йолып калыр өчен барысын да эшләрбез...– Һәм ул өстәлдәге телефоннан кем беләндер сөйләшеп, мине төнге профилакторийга урнаштыруны җайлады.– Операциягә кадәр тәнеңә бераз ит кунсын,– дип юатып, елмаеп калды.

Уңышлы ясалган операциядән соң да Алимә апа мине шул ук профилакторийга урнаштырды.

Аяз еш кына: «Без маргарин белән итек кенә майлыйбыз»,– дип масайса да, ул елларда ашау яклары такы-токы гына иде шул. Ә хәрби завод үз авыруларын бик әйбәт тукландыра. Бүлмәләр дә иркен. Димәк, язгаларга да була. Бу юлы мине фотохәбәрче Образцов белән ике кешелек палатага урнаштырдылар. Мин, гадәттәгечә, үземне «Шамил» дип кенә таныштыргач, ул тел бистәсе: «Ә мин – Мәскәүнең шанлы курчакчысының туганы булмасам да, шәһит киткән бөек политкомиссар Шамил Усмановка турылыклы ординарец булып йөргән орденлы Иван Образцовның туганы!» – дигәч, мин дә җавапка «кесәгә» кермичә: «Ә политкомиссар Шамил Усманов – минем җизнәкәй: ул минем туганнан туган апам, күренекле беренче җырчыбыз Асия Измайлованың ире булган!» – дип җаваплादым. Бу – тарихи факт!

Шушы сүз бүлмәдәшемдә комарлык уятты булса кирәк, икенче көнне үк ул: «Менә бу – тарихи факт!» – дип, Иван Образцов белән политкомиссар Шамил Усмановның янәшә басып төшкән фотосурәтен өстәлгә китереп салды. Икесе дә

кызыл йолдызлы фуражкадан. Образцов бил һәм инсә каешлы тулы хәрби киемнән. Күкрәгендә ордены да күренеп тора. Усманов галифиле кара костюмнан, ак күлмәк һәм яшел галстуктан. Аягында ялтырап торган күн итекләр. Сурәт астына «1920 ел» дип язылган.

Күңелләребезгә якын бу ике кешенең фаҗигале язмышы турында төне буе диярлек сөйләшеп чыктык.

Ә «1920 ел» дип сурәт астына язылган сүзләр миңа 1943 елны исемә төшерделәр. Ул елда мин Яшел Үзән (Зеленодольск) шәһәрендәге 12нче һөнәр училищесында укый идем. Әни кушып җибәргәнчә, ял көннәрендә туганыбыз Сафиулла Измайловларга еш баргалый идем. Шулай бер вакыт, Сафиулла бабай да, Әсмабикә әби дә өйдә юк чак туры килеп, аптырап утырмасын әле бу абый, диптер инде, Элеонора (Гандәлиф апа кызы, танылган рәссамыбыз Г. Е. Трофимовның бертуган апасы), гаилә альбомы китереп тоттырды. Кемнәрнең сурәте генә юк анда! Мин таныганнар шушы гаиләдәгеләр генә һәм әти-әнисе, балалары янына кайткалаган, мин дә күргәләгән артисткалар: Асия, Гандәлиф, Рәйхана, Зита-Зәйтүнә, Хәдичә апалар. Алар ул чакта барысы да йә госпитальләрдә, йә сугышчыларга концерт кую өчен алгы сызыкларда булганнар.

– И вот муж Рәйхана апы – җизни Барый Кадерметов[1]. Он без вести пропал,– диде Элеонора. Аннары авыр сулап кына өстәп куйды: – Это их сын Рафаил. Погиб недавно. Это вот Шакир абый – дипломат. Тоже погиб... 1937-м году...

Икебез дә тынып калдык. Йомшак күңелле сеңелкәш, яшькә тыгылып, аш ягына кереп китте. Мин исә, 1937 елны Испаниядәге хәлдер бу, дип уйлап, альбомны актаруымны

[1] Майор Барый Кадермәтовның кушаматы «Кудров», 1941 елдагы Смоленск тирәсендәге тигезсез каты сугышларда чолганышта калып, урманнарга таралышкан гаскәриләрне туплап, партизан отряды оештыруын мин Казан трамвайчысы, ахырдан Советлар Союзы Герое исеме бирелгән И. К. Кабушкин турындагы «Кайдан син, Жан?» исемле повестьта язган идем инде. Бу документаль әсәр 1969, 1979 елларда – татарча, ә 1976 елда – белорус телендә, 1974, 1981 елларда русчага тәрҗемә ителеп басылып чыкты.

Майор Кадермәтов Совет хөкүмәте тарафыннан «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнде.

дәвам иттем. Иң күп сурәтләр – мәшһүр артисткабыз Асия апаныкы. Сурәтләр артына төшерелгән еллары гына язылган. Тукта! Менә монысында сурәт төшерелгән ел – «1928» ел да һәм: «Свобода любит красоту, красота – свободу!» дигән фәлсәфи мәгънәле сүзләр дә бар. Ахырдан шул билгеле булды: Казанга килгәч, Асия Измайлованың җырлавын бик ошатып А. М. Горький истәлеккә дип язып калдырган икән ул сүзләрне.

Боларның һәммәсен мин күренекле драматургыбыз Аяз Гыйләҗевкә сөйләдем. Ул тәмам кабынып китте. Һич онытылмас зур шәхес Шамил Усманов турында бик шәп драма-фаҗига язу өчен күптән хыялланып йөрүен, тик тарихи мәгълүмат туплауның авыр һәм акрын баруын әйтте.

– Монда, парин, кайберәүләр кебек риваятьләр буенча гына язып булмый. Алай ярамый! Тарихыбызда төрле яктан тирән эз калдырган, гомере бер гөнаһсызга канлы фаҗига белән чикләнгән гыйбрәтле, олпат, зур шәхес ул! Фактик мәгълүматлар җыю өчен, боларның нәрсә икәнлеген син яхшы беләсең, архивларда шактый казынырга кирәк. Иң кирәклеләренең көн яктылыгына чыгарылмавы да ихтимал, – диде.

Әмма гаять четерекле бу авырлыкларны да җиңү юлларын тапты ул: архивларда казынуны тарихчы-галим, атаклы «чаянчы» һәм үзендә дә шундый әсәр язу теләге, хәтта кайбер күренешләре дә тиз-тиз кәгазьгә төшерелгән «караламалары» да булган Альберт Яхинга йөкләде.

Алар икәүләп нык эшләделәр һәм менә дигән драма – «Шамил Усманов»ны иҗат иттеләр. Бу әсәр 1967 елда Г. Камал исемендәге дәүләт академия театрында күренекле режиссерыбыз Марсель Сәлимҗанов тарафыннан чын фаҗига-драма итеп сәхнәләштерелде. Күпчелек җәйге гастрольләр шушы уңышлы спектакль белән башлана иде. Ә инкыйлапның 50 еллыгы хөрмәтенә ул Мәскәү сәхнәсендә уйналды. Булдыклы һәм җитез политкомиссар ролен киләчәккә зур өметләр уяткан талантлы артистыбыз Наил Дунаев башкарды. Тетрәндергеч, гаять уңышлы тамашаны сәхнәдә оста сурәтләнгән вакыйгаларның җанлы шаһиты, мәшһүр җырчыбыз, Мәскәү консерваториясе профессоры

Асия ханым Измайлова да карады. Күзләрендә мөлдерәмә яшь иде аның... Тамашачыларның көчле алкышларыннан зал тетрәп торды. Сәхнә чәчәкләр белән тулды.

Спектакльнең кысасы, табигыйдер ки, милләтебезнең алтын баганалары булган күренекле язучы, җәмәгать эшлеклесе, гражданнар сугышы батыры Шамил Усманов, аның хатыны, мәшһүр актриса, Мәскәү консерваториясе профессоры Асия Измайлова, аның абыйсы, Татарстанның беренче Халык хезмәте комиссары, ахырдан СССР илчелек дипломаты Шакир Измайлов һәм шушы зур шәхесләр белән тыгыз бәйләнештә булган шөһрәтле Алимбәкләр гаиләсе турындагы гыйбрәтле хәлләрне үзенә сыйдыра алмаган. Эпопеякыйсса сериалына дәгъва итәрлек шул алар үткән данлы юл һәм шуның шаукымлы «әҗере» булган канлы 1937–1938 елларда кичергән коточкыч фаҗигаләр.

Аяз 1961–1963 елларда Мәскәүдә Югары әдәби курсларда да мине онытып бетермәде. Янына хәл белергә кергәч, гадәтенчә, тирги-тирги, теге чакта бүләк алган комедияләрне русчага тәрҗемә иттерергә үгетләде. Һәм алар Мәскәүдә басылып та чыктылар.

«Ярдәмчел» дигәнемне куәтләп, әдәбиятның үткер таулы-ташлы сукмагына баскан тәҗрибәсез яшьләргә генә түгел, шул «чир» белән интеккән өлкәннәргә дә – бу ике төркемгә кергәннәрнең шактыена – кулыннан тоткандай җитәкләп олы юлга чыгарга, ә кайберләренә мәһабәт тауның түбәсенә күтәрелергә дә булышучы кешелекле кеше Аяз Гыйләҗев булды! Үзе моннан зыян күрмәде ул. Киресенчә, колачы киңәйде, сулыш алулары иркенәйде. Сабанга чыккан таза аттай эшләде.

Хәзер мин, юбиляр әсәрләренең үземә иң ошаганнарының исемнәрен, күңелемнән изге дога кылгандай рухи халәтем белән, җепкә сәйләннәр тезгән озын тәсбихка тиңләп, сезгә тәкъдим итәм, кадерле милләттәшләрем.

Оста прозаик һәм драматург Аяз Гыйләҗевнең, төпсез дәрья төпләренә чуммаса да, «Зәй энҗеләре»н табып, язгы кар суларын ерып, ябык җилкәләрендә чәчүлек орлык күтәреп кайткан хатын-кызлардан һәм яшьүсмерләрдән торган «Язгы кәрваннар»ны исенә төшереп, иренен тешләп, бу

җәбер-мәсхәрәгә нәфрәтләнеп, алар янәшәсеннән атлавын күргәндәй булам. Ул: «Мәхәббәт һәм нәфрәт» янәшә йөри, шуңа күрә уяу һәм сабыр була белегез,– дигәндәй, «Җиз кыңгырау»ны чылтыратып,– уяныгыз, аска иелгән башларыгызны күтәрегез,– дип искәртеп, «Ефәк баулы былбыл кош»ны гыйбрәт итеп күрсәтеп, тора-бара «Җомга көн, кич белән...» изге дога укыгандай бик нечкә, бик үтемле үгет-нәсыйхәтне анык сурәтләде һәм ифрат та тәэсирле, кешеләрне тирәнтен уйландыра торган «Кичке әңгәмәләр»не үткәрде. Үзенең тормыш тәҗрибәсе зур, күзләре һәм күңел офыклары еракка төбәлгән булганлыктан, әлбәттә, болытлы көннәр килгәләгәндә «Көзге ачы җилләрдә» дә куе болытлар арасыннан адәм баласының кыйбласы сыйфатындагы «Киек Каз Юлы»н күрә алды. Әйе, илаһи көчләрнең мәңгелек хәрәкәттә булуына инандырып, яз җиткәч «Шомырт чәчәк атканда», бүтән җитди проблемалар белән беррәттән, киң Идел шаулавыдай пакь сөюнең тирән хисле, туры һәм көчле агышлы булырга тиешлеген искәртте; «Эңгер-меңгер»дә «Кара күзле кызлар»га күз кысты, «Яланаяклы кыз»ны юатты, «Әтәч менгән читәнгә» дип шаярткан булып, асылда көйдереп, һәммәбезгә төпле акыл-сабак бирде, тормышның матурлыгын күрә, мохитне, кешеләрне таный белергә өндәде.

«Мохит» дигән җәһәттән, «Өч аршын җир» әсәрен һәм күренекле режиссер Марсель Сәлимҗанов сәхнәләштергән спектакльнең безне аеруча тетрәндерүен әйтми калдыру һич ярамас. Ул – Аязның затлы сәйләннәрдән тезелгән иҗат тәсбихенең күктән сузылып төшкән очы, яңгыр тамчысыдай, иң мәртәбәле, иң сихәтле бисмилласы иде, дияр идем мин! Без кичергән шаукымлы авыр елларда тырыш, уңган җир улларын мәкерле план буенча юк итүгә китергән фаҗигане тәфсилләү, ай-һай, бик хәтәр нәрсә иде бит.

Тәсбих тарту тәмамлангач, нәтиҗә ясау һәм теләк теләү фарыз. Нәтиҗә болай: мөхтәрәмебез Аяз Гыйләҗев – дүрт дистәләп менә дигән драма әсәре, шуннан шактый ук артык икътисади-публицистик хезмәтләр, һәммәсеннән диярлек телевизион һәм киң экранлы кино-тамашалар ясарлык хикәя, повесть һәм романнар авторы. Бик зур иҗтиһад бу! Һәм шунысы иң мөһим: Аяз Гыйләҗев – иҗатында туры карап

бара торган кыйбласын кулына каләм алгач ук табып, шуңа һич чигенмәс дәрәҗәдә инанып, шуңа гомере буе тугрылыклы булып калган бәхетле әдип. Һәр әсәрендә диярлек кырыс реализмның өстенлек итүе, шул изге иманның туктаусыз әйдәп торуы нәтиҗәседер. Мотлак шулай! Бу аның соңгы вакытларда дөнья күргән «Балта кем кулында?», «Яра», «Йәгез, бер дога!» һ.б. әсәрләрендә аеруча нык сизелә.

Менә мин «Шамил Усманов»та политкомиссарны сәхнәдә оста гәүдәләндергән Наил Дунайны өендә туры китерә алмагач (балыкка киткән), сеңлемнең бакча күршесе булганга без еш очрашкан районсдашым, гаҗәеп зур талантына күрә, әлләни чаклы дәрәҗәле бүләкләр иясе, ә үзе гадәттән тыш гади һәм күзләрендә дустанә ягымлылык бөркелеп торган Ринат Таҗетдинов белән сөйләшү тәэсиреннән арына алмыйча утырам. «Өч аршын җир» иде сүзебезнең оеткысы. Каршымда йөз чалымнары миңа бик таныш Ринат-Мирвәли. Яшьлекнең саф мәхәббәт чәчкәсен күреп-татып, хезмәттә янып, рәхәтләнеп яшәгәндә генә, замана зилзиләсе дулап, барысын астын-өскә китерә. Чит-ят җирләрдә күргән михнәт-газаплар гүзәл чәчкә – Шәмсегаянны аяктан ега, шиңдерә. Һәм менә Мирвәли, сөекле хатынының ялваруларына буйсынып, ниһаять, сылу гәүдә сузып салынган арбага ат урынына җигелеп, туган авылына таба кайта. Хәләле үз мәетен шунда җирләүне теләде. Әйткән сүзенә һәрвакыт тугры, горур һәм киребеткән, дөньяны үзенчә гадел төстә аңлаган Мирвәли менә басу капкасына җитәрәк, янә эчтән дөрләп яна. Тормышны пыран-заран китергән замана башлыкларын ләгънәтли. Йөзендә – үзәкләргә үтәрлек, тәннәргә себер салкыннары йөгерерлек тирән хәсрәт, газап. Күзләре... Алар вакыт-вакыт ут очкыннары чәчә – нәфрәт, каргышның, үкенү әчесенең чиге-чамасы юк! Бер караңгыдан икенчесенә кадәр тир түгеп хәләл көче белән салган йорт-каралтысына үзе үк ут төртеп киткән, башкаларга да зур зыяны тигән зимагүрне кичерерме авыл халкы? Сөекле Шәмсегаянына, мәңгелеккә-бакый йорты булсын өчен, зираттан өч аршын җир бирерләрме? Менә янәшәдә генә авыл. Болай төзек күренә ул хәзер. Аның корым сарган озын моржалы миче һәм урам яктагы күмерләнеп янып беткән имән капка

баганалары гына... Зират әнә сул якта. Буй җибәреп юанайган талларга, ак тирәкләргә, кайгы билгесе салынган каеннарга да каргалар оялаган.

Тау артыннан кызарып кояш чыгып килә. Тиздән көтүче быргысы яңгырар, капкалар ачылыр, халык малларны көтүгә куа башлар...

Мирвәли, Шәмсегаянның өстенә япкан ак җәймәне ачып, аның сулган йөзенә бакты. Күкләр шаһит: дөньялыкта саф яшәгән газизенең, иншалла, урыны җәннәттә булыр!..

Мирвәли күңелендә бер мизгелдә туган әрнүле уйлар иде болар. Сулкылдавын да сизми калды, кайнар күз яшьләре Шәмсегаянның маңгаена тама башлады. Мирвәли-Ринатның чынлап елаган күз яшьләре иде алар!..

Тамаша залында кабер тынлыгы. Әсәрдәге Мирвәли халәте белән яшәгән олуг сәхнә – сәхнә остасының тирән хәсрәт-кайгысын уртаклашып зал ыңгыраша...

Мирвәли – адәм канын коючы түгел ул! Аллам сакласын!..

Бүгенге зал шуны да аңлый: үз җирендә үзе хуҗа булып, үзенчә эшләп көн күрергә теләгән гаиләнең бәхетсезлегенә, нигездә, тоталитар режим хөкемдарлары гаепле. Йә, киң кодрәтле илаһи көч, юл куйма янәдән шундый коточкыч дәһшәткә, вәхшиләр дә куллана белмәгән бихисап ерткычлыкка!..

Мирвәли исә кешелеген җуймаган, иманга килгән. Әнә ул, күзләрен вакытсыз мәңгегә йомган, явыз көчләр корбанының ак кәфенгә төрелгән мәетен күтәреп, авыл халкы алдына килеп тезләнә...

Гасыр фаҗигасе турында тирәнтен һәм киңрәк уйланыгыз, милләттәшләр, дигәндәй, акрын гына пәрдә ябыла. Кайда икәнлекләрен дә оныта язган тамашачылар әүвәл кыяр-кыймас, аннары көчле алкышлап, барлык артистларны, режиссерны һәм авторны сәхнәгә чакыралар...

Менә икенче лирик чигенеш тә тәмам...

Тәсбихнең соңгы өлеше фаразлаганча, җитмешен тутырган ошбу зур һәм күренекле шәхескә кайбер теләкләребезне дә әйтикче.

Дусларыңның кем икәнлеген белсәм, үзеңнең кем булуыңны әйтермен, диләр. Тирән мәгънә бар бу сүзләрдә. Аяз-

ның дуслары ифрат күп. Кайберләрен генә әйтик: Чыңгыз Айтматов (Пешпек), Виктор Астафьев (Красноярск), Борис Васильев (Мәскәү), Рәсүл Гамзатов (Махачкала), Хейно Вяли (Таллин), Ричардас Гавялис (Вильнюс), Мостай Кәрим (Уфа), Константин Шкан (Кишинев), Раймонд Паулс (Рига) һ.б. Шунысы да игътибарга лаек: болар – төрле милләт вәкилләре һәм төрле һөнәр ияләре. Әдәбиятка алар, Аязның үзе кебек үк, зур сынаулар узып, тормышта чыныгып килгән олуг затлар.

Раймонд әфәнде, мәсәлән, Латвиянең мәдәният министры булган елларында да партия сафларына кермәгән, бөтен гомерен иҗатка багышлаган. Ул менә болай дигән: «һәрнәрсәгә минем үз карашым бар. Мин, кемгәдер ияреп, аны кабатламыйм. Ә бит синең инанган үз кыйблаң булса, бу инде – бик яхшы хикмәт!»

Аязның иҗатта ихлас яхшы киңәшче, җор телле, тирән психологик кичерешләр остасы булуы өстенә әнә шундый «хикмәткә» ия булган зат икәнлеген таныганга күрә, Мәскәүдә аның асыл сыйфатларын күреп алды һәм зурлады: 1987 елда русча тәрҗемәдә Казанда чыккан «При свете зарниц» китабы өчен Россиянең М. Горький исемедәге Дәүләт бүләген бирде.

Ә безнең Татарстан президенты Указы белән 1993 елда Халык язучысы исеменә лаек булды.

Гаҗәп бит: өлгер Аязыбыз драматурглар остаханәсендә хәлиткеч сүз әйтә, яшь әдипләрне язучылар сафына кабул итүдә эшли, съездларда катнаша, идарә әгъзасы буларак абруй казана, әллә ничә басмада редколлегиядә әгъза, укучылар белән даими очраша, бакчасында җиләк-җимеш, чәчәкләр үстерә, Иделдә балык тота.

Алма агачыннан ерак төшми, дигәндәй, олы улы Искәндәр – зур мөмкинлеге булган тарихыбыз галиме, уртанчы улы Мансур Г. Камал театрында бер-бер артлы матур-матур әсәрләрен куйдыра башлады. Төпчекләре Рәшат медицина фәне өлкәсендә тирән белемле, якты уй-фикерле белгеч булып үсеп килә. Хөрмәтле Нәкыя ханым исә әүвәлгечә гаиләнең затлы бизәге – умарта оясындагы анабаш кебек элеккечә биеп, нәсыйхәтләп торсын!

Сүземне түгәрәкләп, шуны да әйтәм: күбебезгә үрнәк булган Аяз Гыйләҗев бүләкләр алыр өчен генә тырышмый. Ул табигате белән шундый! Ул мөлдерәмә тулып ташыган күңелен бушандырмыйча түзә алмый! Ә анда, шөкер, халкыбызны сокландыра торган искиткеч хәзинәләр шактый әле!

Илләр, халыклар иминлеге өчен хуш килгән иҗат юлында озын сәфәр, нык сәламәтлек һәм уңышлар теләп торабыз сиңа, хөрмәтле юбиляр!

*04.04.1998*

***Ида Андреева[1]***

## Мои воспоминания о годах студенчества в стенах Казанского университета

«А мы историю учили не по лекциям, она сама врывалась в нашу жизнь», – так, несколько перефразируя В. Маяковского, я вспоминаю свои ранние студенческие годы. Но начну я с холодной весны 1953 года, когда три подружки-восьмиклассницы стояли, обнявшись, на крыльце небольшого деревянного домика в Адмиралтейской слободе Казани и со слезами на глазах слушали, как над Казанью тоскливо звучат гудки заводов, паровозов, машин. В Москве в это время хоронили того, с чьим именем они становились сначала октябрятами, потом пионерами и комсомольцами и кого привыкли называть «лучшим другом детей» и «отцом» всего нашего народа. Вот такими мы вступали в жизнь в самом начале 50-х годов, когда после окончания школы я пришла в университет. Однокурсники почти все были моими ровесниками и также воспитаны в духе того, советского времени, свято веря в социализм и правильность исторического пути страны. Но вскоре сама жизнь заставила нас многое пересмотреть и понять, как оно в действительности было. Уже после зачисления на первом курсе у нас неожиданно появились студенты гораздо старше нас: поначалу они были мол-

[1] Андреева Ида Ивановна – литературовед, кандидат филологических наук (1975) (С.-Петербург).

чаливы, сдержанны в разговорах, о себе рассказывали мало и одеты были в какие-то черные куртки.

Хорошо помню двоих из них: Валентина Николаева и Аяза Гилязова. Первый был зачислен в мою группу, а второй – на отделение татарского языка и литературы нашего историко-филологического факультета. Иногда можно было увидеть, как друзья уединялись где-нибудь в дальнем углу длинного коридора и долго о чем-то с увлечением говорили. Когда же освоились, то постепенно стали рассказывать, что несколько лет назад были арестованы, исключены из университета и прошли через специальные лагеря (Аяз – в Казахстане, а Валентин – на Северном Урале) за то, что пытались говорить о тяжелом положении в стране и незаконных преследованиях. В своих беседах они хотели выяснить, что сталось с их бывшими сокурсниками, искали общих знакомых. Так, Аяз очень хотел найти следы своего друга-старшекурскника по фамилии Кузнецов, который предупредил его об угрозе ареста за публикации в университетской многотиражке произведений и разговорах о настоящем положении на селе, откуда Аяз приехал в университет. А. М. Кузнецов учился на отделении классической филологии вместе с В. Николаевым. Как оказалось, Александр Кузнецов бросил университет и скрывался от ареста, кочуя по стране. Он был из старообрядческой семьи. Когда в мои руки попал перевод романа А. Гилязова «Давайте помолимся!», я узнала, что поиски друга юности увенчались успехом, и он приезжал в гости к татарскому писателю. К слову, я всегда восхищалась тем, как ценили дружбу мои старшие друзья по университету. Они умели дружить. Несмотря на угрозу новых гонений, искали своих друзей, по воле судьбы оказавшихся в разных уголках не только страны, но и мира. (Разве история с Арпадом Галгоци тому не доказательство! Жаль, что воплотить мечту писателя удалось казанскому литературоведу М. М. Хабутдиновой после ухода из жизни Аяза Гилязова).

В. Николаев был арестован в 1948 г. За «агитацию на срыв мероприятий советской власти» он получил 8 лет. Вновь сел за студенческую парту КГУ в 1955 г. В 1956–1958 гг. В. Николаев учился параллельно с А. Гилязовым на отделении

русской филологии. Я была старостой группы. Как-то меня вызвали в деканат, где замдекана Мансур Хасанов, отвечавший за идеологическую работу, предупредил меня о личной ответственности за то, чтобы бывшие «лагерники» не сближались со студентами и не вели с ними политические разговоры. Однако обстоятельства сложились так, что мы быстро подружились с опальными студентами.

Со временем мы узнали и причину пребывания Валентина Николаева в лагере: оказывается, он и несколько его друзей на факультете (имен он, естественно, не называл), ни много ни мало, готовились к отказу участвовать во время очередных выборов и вели об этом разговоры среди студентов (отсюда и обвинение: «систематическая агитация на срыв мероприятий советской власти»). Кто-то донес о готовящемся саботаже. Валентин был арестован и осужден, но о других арестах он ничего не рассказывал. Очевидно, что они тоже были. Естественно, что после этого сообщения наше уважение к такому сокурснику неизмеримо выросло.

Именно эти старшие товарищи, уже прошедшие через лагеря, обратили наше внимание на то, что даже после осуждения культа личности Сталина в стране пока что мало изменений. Мы и сами убедились в этом сначала во время поездки на уборку урожая в колхоз (что было в те годы обязательной для нас повинностью), где увидели не заинтересованность колхозников в своей работе, так как она их не кормила: почти весь урожай шел «в закрома Родины», как тогда говорили. Держалось же село исключительно на своих огородах, слепо выполняя все «директивы сверху». Помню, как недоумевал старик-механик, без конца ремонтируя выходившую постоянно из строя силосорезку: зачем сажать кукурузу, если она в здешних местах плохо растет, а корм из нее коровы не едят. В итоге на первых же практических занятиях по истории КПСС мы стали задавать нашей преподавательнице «неудобные вопросы» про эту самую кукурузу и тогдашнюю политику генсека Хрущева относительно сельского хозяйства. Сразу после этого к нам на занятия пришел парторг университета с «разъяснениями» этой самой «политики», но время было другое, поэтому «репрессий» в адрес вопрошающих

«крамольников» не последовало. Но зато между собой мы активно обсуждали вопрос о том, почему студент В. Ульянов за участие в студенческой сходке, хотя и был исключен из университета, но сослан всего лишь в семейное имение под Казанью (а не в Сибирь и не в лагеря), где имел возможность готовиться к сдаче экзаменов экстерном. А потом все свои подобные вопросы мы перенесли на знакомую нам литературную ниву.

Помню, как остро проходили заседания нашего литературного кружка, где часто обсуждались новые литературные произведения. Я еще застала на первом курсе тогдашнего председателя кружка Ефима Клебанова, который рассказывал нам о горячем обсуждении на заседании кружка повести Ю. Трифонова «Студенты» в 1952 году. Студенты написали письмо автору, так как не согласились с мнением своих преподавателей о слабости и искажении послевоенной жизни в этом произведении.

Громкая история случилась накануне моего поступления в университет, в 1954 г. О ней писал и известный критик Игорь Золотусский, выпускник нашего факультета. Тогда состоялось обсуждение студентами-филологами статьи В. Померанцева в «Новом мире» – «Об искренности в литературе», «на которое собрался весь город и после которого последовали вызов в партком и комитет комсомола, поиск зачинщиков и сочувствующих студентам преподавателей». Именно в результате этой истории была вынуждена уехать в Волгоград (в Сталинградский пединститут) обожаемая студентами доц. Е. А. Слободская, преподававшая зарубежную литературу и бывшая зав. кафедрой с 1946 по 1954 год. Правда, тогда никого из студентов из университета не исключили. А уже во время моей учебы на 2-м курсе была отправлена на пенсию замечательный специалист, доц. Г. А. Вишневская, неугодная тогдашнему руководству кафедры. Однако вокруг нее образовалось и некоторое время функционировало небольшое «закрытое литературное общество» на квартире Г. А. Вишневской на ст. Обсерватория. Об этом поведал в свое время Р. Кутую известный краевед, историк Казанского университета и мой однокурсник В. Аристов, которого

за посещение этого общества «чуть было не исключили из университета».

Лекции эти были потоковыми, т.е. читались всем 4-м группам курса (группа историков, 2 группы русистов и татарская группа, т.е. татарского языка и литературы). После лекций часто В. Николаев уходил с невысоким студентом из татарской группы.

Дважды, после первого и второго курсов (в 1956 и 1957 годах), мы, как и студенты всей страны, помогали убирать большой урожай зерна на осваиваемой тогда целине. Это было интересное и незабываемое время. Наш большой университетский отряд попал в Казахстан, в Павлодарскую область (недалеко от нынешней столицы этой республики). Мы скирдовали солому за комбайном, работали на току и погрузке зерно в вагоны – словом, познавали настоящую трудовую жизнь, натирая мозоли и стараясь стойко переносить 40-градусную жару днем и очень холодные вечера. И только удивлялись тому, как наш одногруппник В. Николаев все это переносит не просто спокойно, но с улыбкой и шутками, называя настоящим «курортом». Вот тут-то мы и «вытягивали» из него лагерные воспоминания и рассказы о трагических судьбах тех, с кем он там был. Среди них оказалось много ученых, профессоров, университетских преподавателей, благодаря которым Валентин и продолжил свое «образование» в лагерном бараке, поэтому удивлял нас и преподавателей своими обширными знаниями. О таких же «учителях» с благодарностью вспоминал позднее и А. Гилязов в своем автобиографическом романе «Давайте помолимся!».

Однажды мы услышали от местных жителей о том, что недалеко от нашего совхоза «Казанский» (был основан комсомольцами из Татарстана) находится чеченский аул. О чеченцах мы что-то знали из истории многолетней войны России на Кавказе, а еще из произведений Пушкина и Лермонтова (все-таки филологи!). И вот мы решили посмотреть на этих воинственных «детей» Кавказа. Уговорили солдата-шофера из автобата, который располагался рядом, загрузились в его полуторку и поехали. Но в ауле за нами сразу же поскакали всадники на конях, потрясая настоящими винтовками.

Испугались не только мы, но и солдат-водитель, который погнал машину на полной скорости, и скоро преследователи отстали. А по возвращении Валентин рассказал нам, почему чеченцы оказались так далеко от родных мест и ведут себя столь воинственно. Так мы узнали о депортации чеченского народа с Кавказа в начале Великой Отечественной войны якобы как предателей родины (и опять вопрос у нас в головах и друг другу: что, весь народ – предатели?) А на следующий год, когда мы работали в казахском колхозе им. Чапаева, от нашей поварихи-местной жительницы Эммы (все удивлялись поначалу ее не казахскому имени!) услышали историю о переселении буквально в считанные часы ее семьи в числе всех немцев Поволжья с берегов Волги (т.е. почти из наших, родных мест) в далекие казахские степи в то же самое время, что и чеченцев, и то той же причине. И опять в предательстве подозревался весь народ, о существовании которого мы даже не слышали.

Вот так сама жизнь и наши старшие однокурсники помогали нам узнавать настоящую историю своей страны, потому что не боялись встать за правду, задавать открыто острые политические вопросы, что мы и старались от них перенять и сохранить в своей дальнейшей жизни.

А. Гилязов вскоре бросил учебу. От Николаева я узнала, что Аяз уехал учиться на Высшие литературные курсы. После окончания университета, в годы преподавательской деятельности, мне не раз доводилось встречаться с ним в стенах университета. Я бережно храню книгу моего друга юности «Три аршина земли», опубликованную в Москве, с его автографом. До сих пор помню, как они с Вилем Ганиевым пришли в университет на встречу со студентами. Мы вместе радовались успеху А. Гилязова, получившего премию журнала «Дружба народов».

У писателя А. Платонова есть такие слова: «Без меня народ неполный». Опять-таки перефразируя их, хочется сказать, что история студенческого свободомыслия в Казанском университете, которая уже начата исследованиями многих его известных ученых, только тогда станет до конца полной, когда в ней будет рассказана история всех его бунтующих

свободолюбивых студентов, таких, как А. Гилязов (ставший Народным писателем Республики Татарстан), и В. Николаев (кроме университета, он затем окончил Казанский авиационный институт и долгое время работал инженером на заводе «Газоаппарат»).

*2023*

***Разил Вәлиев***[1]

## Гомеремнең аяз көннәре...[2]

Аяз ага белән ныклап танышып, якынаеп китүем һич көтмәгәндә-уйламаганда булды. Минем Мәскәүдә – әдәбият институтында укып йөргән чагым (1967–1972). Казанның рухи кысанлыгыннан соң Мәскәүнең чагыштырмача хөр фикерле мохитенә килеп эләккәч, башта бераз аптырап та калган идем. Әмма бу халәткә тиз ияләштем, бер ел эчендә бераз Мәскәүчә уйларга, Мәскәүчә яшәргә дә өйрәнә башладым кебек. Кем әйтмешли, кесәләр буш булса да, күңелләр хуш, йөрәкләр куш чак... Ул заманда безнең кулдан килмәгән бер эш тә юк сыман иде. Мәскәүдә беренче очраган татар кызына гашыйк булып, берничә айдан аңа өйләнеп тә җибәрдем, озакламый Сөембикә исемле кызыбыз да дөньяга килде. Бала белән тулай торакта яшәргә ярамый, дип куып чыгаргач, Мәскәү читендәге бер иске дачага барып сыендык. Гаилә асрарга кирәк булгач, төннәрен заводта тимерчелек цехында эшли башладым.

Менә шулай шау-гөр килеп, очын-очка ялган яшәп ятканда, Казаннан мәшһүр язучыбыз Аяз Гыйләҗев килүе хакында хәбәр ишетелде. Җитмәсә, әле ул безнең тулай торакның кунакханә бүлмәсенә урнашкан икән. Аяз ага – минем өчен гыйбрәтле язмышы белән дә, олы иҗаты белән дә

[1] Разил Исмәгыйль улы Вәлиев (1947) – татар язучысы, шагыйрь, күренекле җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, Татарстанның халык шагыйре, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2007), Татарстанның М. Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты.

[2] Вәлиев Р. Гомеремнең аяз көннәре... // Ватаным Татарстан. – 2006. – 27 гыйнвар.

буй җитмәслек илаһи шәхес. Казанда дөнья күрә алмыйча Мәскәүдә басылып чыккан «Өч аршын җир» повестеның шаулаган еллары. «Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына» дигәндәй, институтта лекциядән чыгып барганда ишегалдында Аяз аганы күреп алдым. Югары әдәби курсларда укучы шагыйрь Рәдиф Гаташ белән кызып-кызып әңгәмә коралар иде болар. Кул бирешеп исәнләшкәндә, Аяз ага үткен күзләре белән мине аяк очларымнан баш түбәмә кадәр сөзеп чыкты да: «Шушы буламыни инде, «урыс капкаларын каерып ачучы егет?» – дип көлемсерәп куйды. Минем әле генә «Казан утлары» журналында чыккан шигырьләремнән хәбәрдар икәнен аңлагач, кинәт канатланып киткәндәй булдым. Аяз абый белән ике арадагы бушлык күз ачып йомганчы юкка чыкты. Тулай торакка кадәр таксида кайтканда да, Рәдиф бүлмәсендә озаклап чәй эчкәндә дә мин Аяз ага сүзләренең сихеренә бирелеп, телсез калгандай берни дәшми тыңлап тордым. Ул моңа кадәр мин ишетеп кенә белгән, әсәрләре «идән астыннан» гына таратылган Солженицын, Гумилев, Пастернак кебек тыелган язучылар, үзебезнең Исхакый кебек мөһаҗир затларыбыз хакында шулкадәр тәфсилләп һәм тәмләп сөйли ки, мин, ирексездән, әле генә дөньяга килгән сабый бала кыяфәтендә авыз ачып тыңлыйм да тыңлыйм.

Мәҗлес ахырында ул Рәдиф белән миннән яңа шигырьләребезне дә укытты. Бераз мактап, салпы якка салам кыстырып та алды. «Языгыз, көнне-төнне белмичә языгыз, сезнең әле шашып яза торган чагыгыз! Сезнең яшьтә мин дә шигырь яза идем, парин. Өч чемодан шигырем әле дә дачада ята»,– дип һаваланып куйды ул. Монысы безне котырту өчен генә булгандыр инде, дип уйладык. Ул сүзен дәвам итте: «Әмма әйтәсе сүзне шигырьгә генә сыйдырып булмый. Әнә Пушкинны, Лермонтовны, Пастернакны алыгыз. Бөекләрнең пакусы киң була. Проза да языпкарагыз сез... Рәдиф бөегебез – коеп куйган шагыйрь инде ул, шуңа күрә проза белән вакланып, җиргә төшеп тормас, ә менә сиңа ныклап торып киңәш итәр идем...» Шулчак мин хыялга бирелеп: «Минем язган повестем бар инде»,– дип әйтеп ташлаганымны сизми дә калдым. Ә чынында бу – шагыйранә ялган, әлеге повесть кәгазьгә төшмәгән, ә бары тик минем күңел түрендә генә

бөреләнгән иде. Аяз аганың: «Мин әле Мәскәүдә бер атна торам, эшләрем беткәч, китәр алдыннан дачаңа кунакка килермен, повестеңны әзерләп куй, бергәләп укырбыз»,– дигән сүзләрен ишеткәч, бөтен тәнем кызыша башлады.

Инде нишләргә? Бер атнадан Аяз ага минем повестьны укырга киләчәк, ә аның әле бер бите дә язылмаган. Минем гомеремдә бер тапкыр да мондый ахмак хәлдә калганым юк иде. «Бу – һич тә алдашу түгел, чынлыкта повесть инде күңелемдә оешып җиткән, аны дөньяга китерәсе, кәгазьгә төшерәсе генә калган»,– дип үз-үземне юата-юата, «Перловка» станциясендәге иске дачага кайттым да өстәл янына кадакланып утырдым. Ярый әле институтта каникул вакыты – укырга йөрисе юк. Мин көнне дә, төнне дә онытып яздым да яздым. Хатыным Алия куйган чәйне эчәргә генә бүленәм дә тагын кәгазь өстенә капланам. Тәүлегенә егерме-егерме бишәр бит яза торгач, Аяз ага киләсе көннең таңында мин «Эт кояшы» дигән повестемны тәмамладым. Атна эчендә җиңеләеп калган гәүдәмнең авырлыгын да тоймыйча, Аяз аганы алып киләчәк электричка янына очып, канатланып барам... Гомумән, кешеләргә, бигрәк тә яшь-җилкенчәк язучыларга иҗат дәрте өстәү, канат кую – Аяз аганың иң асыл сыйфатларының берсе булгандыр. Дөрес, вакыты-вакыты белән ул бик кырыс, таләпчән, хәтта усал да була белә иде. Әмма нигәдер хәтеремдә боларның берсе дә тирән уелып калмаган, ә инде заманында күңелемә ул салган иҗат кузлары әле хәзер дә вакыт-вакыт кызыша башлап, йокыларны качыра, кулга каләм алырга мәҗбүр итә.

Ул безнең шактый таушалган кечкенә дача кисәген мактау өчен дә матур сүзләр тапты, ике каен арасына тартылган таганга утырып, көлә-көлә атынып та алды. Шушы «хан сарае» өчен аена күпме түләгәнебезне дә сорарга онытмады, өстәвенә, Рабит Батулладан калган вак шрифтлы борынгы язу машинасын күргәч, «нәшриятлар мондый стандартны кабул итми» дип кисәтеп тә куйды. Ул һәр нәрсәне күрә, һәрнәрсәгә игътибар итә, аның һәрнәрсә хакында үз фикере, һәр кешегә, һәр вакыйгага үз мөнәсәбәте бар иде. Шулчак мин эчтән генә: «Чын язучы, чын прозаик шундый булырга тиештер инде»,– дип уйлап куйдым. Алиянең аннан-моннан

юнәтеп пешергән пылавын мактый-мактый ашаганнан соң, ул: «Әйдә, күрсәт инде шедеврыңны!» – дип, йорт хуҗасыннан калган шыгырдавык диванга җайлап утырды. «Мин аны машинкада басарга өлгермәдем бит, кулъязма хәлендә генә ул», – дип ык-мык килә-килә аклана башлаган идем, моңа да исе китмәде. (Югыйсә аннан: «Ярый алайса, Казанга машинкада бастырып алып кайтырсың, шунда укырмын», – дип, әйтүен көткән идем.) «Прозаны кулдан язып торма син, турыдан-туры машинкада басарга өйрән. Шулай җайлырак ул, язганың күзгә ачык күренеп тора. Әйдә алайса, син кычкырып укы, мин тыңлармын», – диде.

Моңа кадәр инде күп мәртәбәләр имтихан биргәнем булса да, монысы минем тормышымда иң авыр, иң җаваплы сынау булгандыр. Әгәр повестьны укып бетергәннән соң, Аяз ага миңа «икеле» куйса, бәлки, киләчәктә бөтенләй иҗат эшенә кул селтәгән, һич югында үз-үземә ышанычым бик нык кимегән булыр иде... Мин өч сәгать буена берөзлексез укыдым да укыдым. Аяз агага күтәрелеп карарга да куркып укыдым. Әгәр шулчак ул туктатып, берәр авыр сүз әйтсә, минем бөтен хыялларым, бөтен өметләрем, бөтен дөньям бер мизгелдә челпәрәмә килер кебек иде. Повестьның соңгы җөмләсен тәмамлагач, мин, ниһаять, Аяз агайга күтәрелеп карадым. Аның йөзеннән хәйләкәр елмаю дулкыннары йөгереп үткән кебек булды. Шулчак ул торып басты да: «Булган бу, парин, – диде. – Әмма күңеленә авыр алма, повестеңны Казанда басулары икеле, Казан – бик тар күңелле, тынчу һавалы шәһәр ул. Маяковский әйтмешли, тәрәзәсен ачып җилләтәсе бар аның. Тик син язуыңны туктатма, бүген басмасалар, иртәгә басарлар, иртәгә басмасалар – берсекөнгә. Дөнья гел болай гына бара алмый ул, дустым».

Саубуллашканда, Аяз ага миңа язу машинкасы алырга акча биреп калдырды. «Пушкин урамында бик шәп «Эрика» машинкасы сата торган кибет бар. Немец машинкасы! Аны Мәскәү кешеләренә чиратка яздырып кына саталар. Икене алырсың, берсе үзеңә булыр. Югыйсә, бу машинкаңда шедевр язсаң да, нәшриятлар кабул итмәячәк», – диде.

Аяз аганың юраганы юш килде. Минем «Эт кояшы» повесте хакында Татарстан Язучылары берлеге идарәсендә фи-

кер алышу оештырдылар. Бәхәс бик кызу булып, арада яхшы гына фикерләр әйтелсә дә, нәтиҗәне нәшриятның ул еллардагы баш мөхәррире ясады. «Мин бу әсәрнең уңай якларына тукталып тормыйм, анысы хакында сөйләделәр инде. Без бүген сүз алып барган повесть совет чынбарлыгын бозып, каралтып күрсәтә. Шундый әсәрнең талантлы каләм белән язылуы аның зыянлы булуын икеләтә арттыра гына. Мин авторга тормышның якты якларына күбрәк игътибар итәргә, әдәбияттагы буржуаз агымнарга иярмәскә тәкъдим итәр идем». Баш мөхәррирнең тешләрен шыкылдата-шыкылдата сөйләвен тыңлаганда, миңа нигәдер кулымдагы зыңҗыр чыңнары ишетелгәндәй булды, күз алдыма, ап-ачык булып, Аяз аганың язмыш шәүләсе килеп басты... Егерме яшьлек студент тарафыннан язылган «Эт кояшы» повесте ил өстендәге куе болытлар бераз тарала төшкәч, егерме ике елдан соң (1990 елда) гына тулысынча басылып чыкты.

Ә язу машинкасын Аяз абыйга барыбер алып кайттым мин. Һәм менә бу язмамны нәкъ менә шул Аяз ага белән бергә алган «Эрика» машинкасында басып утырам. Әмма ул машинкаларны алу җайлы гына булмады. Аяз аганың машинка алырга җыенуын ишетеп, Казаннан миңа тагын өстәмә заказлар килә башлады. Берсеннән дә баш тартып булмый, чөнки һәммәсе дә – мин белгән, хөрмәт иткән мөхтәрәм шагыйрьләр. Тик Мәскәү кибетендә башкала пропискасы булган бер кешегә бер машинка гына саталар. Ә миңа бишне алырга кирәк. Каян табарга тагын дүрт москвичны? Җитмәсә, моның өчен сәгать дүрттән барып Пушкин урамындагы кибет янында чиратка басарга, анда көне буе торып, үз нәүбәтеңне көтәргә кирәк. Ниһаять, үзебез белән бер курста укыган бурят, монгол, калмык, балкар егетләрен ияртеп, чиратка язылдык. Атна саен барып, ел буена чиратыбызның кайсы тирәдә булуын белешеп тордык. Көне җитеп, биш машинканы кулга төшергәч, шул ук егетләр мине «Татарстан» поездына озатып та куйдылар. Вагонда ничек итеп мине «машинка сатучы спекулянт» дип атауларын, проводницага акча төртеп, көч-хәл белән бу бәладән котылуымны тәфсилләп сөйләп тормыйм. Казан вокзалында мине каршы алучы булмады. Инде нишләргә? Таксига акча юк, ике кулга

биш машинканы да күтәреп булмый. Ничарадан бичара, ике кулга икешәр машинканы бергә бәйләп тоттым, бишенчесен тоткасыннан авызга каптым да трамвайга кадәр мүкәләп барып җиттем. Трамвайдан төшкәч, колхоз базарыннан Матбугат йортына да шул рәвештә кайтырга туры килде. Җитмәсә, тирә-юньдәге халык бармак төртеп күрсәтә, арттан көлеп кала. Шулай көч-хәл белән Язучылар йортына кайтып егылдым. Юк, мин боларны һич кенә дә күргән михнәтләремне тасвирлап үземне кызгандыру өчен язмыйм. Боларны искә алуымның сәбәпчесе – әлеге дә баягы мөхтәрәм Аяз ага. Беренчедән, ул мине – әле яңа гына борын төртә башлаган әдәбият чебешен, якты дөньяга чыгару өчен куәт бирде, «мә, эшлә» дип, кулыма корал тоттырды. Аяз абый аркасында мин шәп машинкалы булдым, ул машинка менә инде кырык елга якын минем иң мөкатдәс уйларымны кәгазьгә күчерә, хәзер дә ул мине һәр көнне, ымсындырып, үзе янына чакырып тора.

Мөхтәрәм шагыйрьләребез Илдар Юзеев, Нури Арслан һәм Әхсән Баянга Аяз ага фатихасы белән алып кайткан машинкаларның да әдәбиятыбыз өчен бәрәкәтле әсәрләр бүләк итүенә минем һич кенә дә шигем юк.

Язу машинкасы хакында шулай иркенләп сөйләвем юкка гына түгел. Иҗат кешесе өчен компьютер никадәр генә уңайлы булса да, минем әле һич кенә дә машинкадан аерыласым килми. Моның сәбәпләрен үзем дә аңлап бетермим бугай. Әмма бер сәбәбен беләм: ул – остазым Аяз ага ядкаре. Аяз ага машинкада гаҗәеп җитез һәм оста баса: Святослав Рихтер фортепьянода уйный, диярсең. Вакыт-вакыт аның машинка такылдавы миңа йөгерек фикере артыннан калышмаска тырышып тупырдап чабучы ат тояклары тавышын да хәтерләтә. Ә кайчакта ул, дошман явына каршы ялгыз калган пулеметчыга охшап, ярсый-ярсый тыкылдата да тыкылдата кебек. Аның туктарга, бирешергә исәбе дә юк. Чөнки артта – аның газиз Халкы, газиз Ватаны...

Халкы өчен һәрчак утка керергә әзер кеше булса да, Аяз ага беркайчан да ил, ватан, милләт турында купшы сүзләр сөйләп йөрмәде. «Үзеңнең зурлыгыңны, халыкның бөеклеген бары тик эш белән, акыл белән, мәдәният-сәнгать әсәрләре

белән генә күрсәтеп булла»,– дип кабатларга ярата иде ул. Һәм бу сүзләрне үзенең гаҗәеп мул иҗаты, бөтен тормыш юлы, кылган гамәлләре белән аклады.

*2006, гыйнвар*

***Альтер Литвин[1]***

## Күптәнге дуска хат[1]

Кадерле Аяз Мирсәетович!

Менә инде берничә ел Сезнең белән күрешеп сөйләшә алганыбыз юк, ә бит элегрәк очрашулар һәм телефон аша сөйләшеп торулар көн саен була торган иде. Хәзер башка заманнар, каберегез янына барам да, янәшә басып, истәлек-хатирәләргә күмеләм! Язмышның безне шулай бик тиз һәм кайгылы-фаҗигале рәвештә аеруы бик кызганыч.

Ә бит барысы да Восстание урамында, безнең йортта очрашудан башланган иде. Казан университетының тарих факультетында бергә укучы улларыбыз Саша һәм Искәндәр таныштырды безне. Сез Нәкыя Илһамовна белән безгә килеп кердегез, шунда без дусларча чәй эчү барышында Казандагы 1918 елларның җәй-көз айлары турында бергәләшеп китап язарга ниятләгән идек. Ул чорда илдә Гражданнар сугышы бара, шәһәр йә – кызыллар кулына, йә Учредительное собрание яклыларга күчә. Безне ул чорның аерым кешеләре, бигрәк тә ЧКда хезмәт итүчеләрнең башкаларның язмышлары белән уйнаулары, шул властьтан исерүләре кызыксындырган иде. Мине Казан ЧКсы архивыннан табып алган бер документ шаккатырды. Башка гомерләргә «хуҗа» унтугыз яшьлек бер чекист ярты битлек кенә сорау алудан соң илле яшьлек йорт хуҗасына, аны-моны уйлап тормастан, шундый хөкем чыгара: «Совет властена файдалы була алмаячак. Атарга!» Һәм теге кешене атып үтерәләр. Шундый тизлек һәм җиңеллек белән шуңа охшаш карарлар чыгарылуы Сезне дә тетрәндергән иде.

---

[1] Литвин. А. Күптәнге дуска хат // Казан утлары.– 2007.– № 4.– 151–156 б.

Без иске Казан урамнарында йөри башладык, үземнең элегрәк экскурсовод булып эшләгәнемне хәтерләп, Сезгә Привокзальный (хәзерге Чернышевский) урамы, Болак, Гоголь һәм элек губерна ЧКсы урнашкан Толстой урамнары турында сөйләдем. Без, бергәләп, Зур Проломный (хәзерге Бауман) урамындагы банкның идарәчесе Мансур Галимовтан 1918 елда республиканың алтын запасы тотылган саклагычны күрсәтүне үтендек, комуччылар аны шуннан төяп алып чыгып китәләр бит инде. Ул алтыннар 1920 елда гына һәм яртылаш урланып кына кайтып керә. Тар гына баскычтан төшкәч, галәмәт зур корыч сейф тора, аны 1913 елда Берлинда ясаганнар. Ул безгә көчле тәэсир итте, 1918 елның 6 августында бу подвал берничә сәгатькә бөтенләй саклаучысыз калгач, бирердәге байлыкның нигә шулай аз гына талануын да аңладык.

Аннары без шул чордагы Казан тормышы турында роман-хроника яза башладык. Романдагы бик күп вакыйгалар документларга нигезләнгән иде, кешеләрнең, башлыча тәгаен шәхесләрнең образлары шул заманның җыелма образлары булып, кылган гамәлләрен төрле документлардан, истәлекләрдән, төрле тикшеренүләрдән дә җыйган идек.

Иҗади эшебезне болай оештырдык без: мин сюжет сызыгын билгелим дә, аннары аны икәүләп тикшереп чыгабыз. Сез миңа текстның беренче вариантын: вакыйгаларны сурәтләү, андагы шәхесләрнең монолог һәм диалог-әңгәмәләрен кәгазьгә төшерүне йөкләдегез. Сез русча язылган текстны ала идегез дә аның татарча вариантын үз кулыгыз белән әдәби телдә язып чыга идегез. Улыгыз Искәндәр Сезнең вариантка юлга-юл русчага тәрҗемә эшли, шуның нигезендә мин русча соңгы текстны язам.

Без бу романны рус телендә дә, татар телендә дә бастырып чыгардык. Аерым өлешләрен, кисәкләп-кисәкләп, «Казан утлары» журналында да бастырдык. Роман күпмедер вакытка иң яратып укыла торган әсәргә әйләнде. Җирле чекистларның аерым тәнкыйть сүзләренә дә карамастан, Дәүләт иминлеге (КГБ) әдәби премияләре конкурсына җибәрелгән роман, гаҗәпләнүебезгә каршы, безгә лауреат медальләре ирештерде. Мактау грамоталары һәм «Зоркий» фотоаппа-

ратлары белән дә бүләкләделәр әле үзебезне. Ул бүләкләр хакында без фикер алышып тормадык, болар безгә иҗат эшебезне тыныч-имин дәвам итү мөмкинлеге бирер, дигән мәгънәдә карашып кына алдык.

Шуннан соң без сугыш кырын ташлап качкан Петроград эшче полкының һәр унынчы сугышчысы 1918 елның августында атып үтерелүгә багышланган «Реввоенсовет» дигән пьеса яздык. Еш кына хаксыз булган хөкем карарларын башкарган чекист палачы турында, аның психологик язмышы хакында «Идел» журналында «Мостафа» дигән повесть бастырдык.

Без Сезнең белән илебезнең дистәләрчә еллар дәвамында мәҗбүр итү һәм көчләү шартларында яшәгәнен ишетеп кенә белмәдек, моны үз күзебез белән күреп тордык. Без бу шартларны тудырган, кадерләп саклаган һәм барлык «җинаятьчел боерыкларны» үтәгән затларны аңларга тырыштык. Бергәләп, сәяси корбаннарга карата булган репрессияләрне күрсәтеп, документаль киносценарий яздык, Евгения Гинзбург, Галимҗан Ибраһимов, Василий Слепков, Кәрим Тинчурин, Хәсән Туфан һәм күп кенә башкаларның «җинаять эшләре» турында сөйләп бирергә теләдек, шунда ук аларның палачларын да күрсәтмәкче идек. Ни өчендер Казан телевидениесе аны кабул итмәде, шулай булса да, мин ул сценарийны һаман саклыйм әле. Без Сезнең белән 1919–1920 елларда Казанда булып үткән вакыйгалар турында «Убыр» («Оборотень») дип исемләнгән бик мавыктыргыч фильм иҗат итәргә теләк белдергән идек. Әмма җирле телевидение моны да хупламады.

Иң мөһиме: һәркайсыбыз аерым-аерым эшләсәк тә, иҗади хезмәттәшлекне дәвам итә килдек.

2004 елда Казан университеты үзенең 200 еллык юбилеен бәйрәм итте. Шул вакытта бу борынгы уку йортының хезмәткәрләре һәм аны тәмамлаучыларга багышланган күптомлы биобиблиографик сүзлек әзерләнә башлады. Төрле хәлләр аркасында университетны тәмамлап чыга алмый калсагыз да, мин Сезнең хакта очерк язуны намус эшем дип санадым. Бу энциклопедик басмага әзерләнгән башка мәкаләләр шикелле үк, очерк кыска гына язылган иде. Мин,

аны әзерләгән чакта, зур кызыксыну белән, Сезнең университет архивында сакланып калган «эш»егезне укып чыктым. Ниндидер моңсу гаҗизлек хисе белән, Сезнең хакта Казандагы КГБ идарәсе архивындагы тикшерү «эш»ен дә карап алдым.

Сезнең студентлык елларыгыз хакындагы материаллар 69 биттән тора икән. Ул 1945 елның 28 июлендә ачылган да 1957 елның 28 октябрендә ябылган. Әлеге 12 ел эчендә Сезнең белән нинди хәлләр булган соң? Үзегез язган автобиографиядән күренгәнчә, Сез Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында 1928 елның 17 гыйнварында укытучы гаиләсендә тугансыз. 1930 елда әти-әниегез эшкә Югары Баграж мәктәбенә күчеп килгәннәр. Сез шунда башлангыч мәктәпне, 1945 елда Сарманда урта мәктәпне тәмамлагансыз. Сакланып калган өлгергәнлек аттестатыгызда унике «бишле», өч «дүртле» һәм бары тик физикадан гына «өчле» билгесе тора.

Шул елда ук, 1945 елның августыннан, Сез – унҗиде яшьлек егет – Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге студенты. Сезнең зачёт кенәгәсендә курсның 1нче семестры өчен имтиханнар тапшыруыгыз турында да мәгълүматлар бар. Сез бик авыр тормышта, ярлы яшәгәнсез. Декан исеменә язган гаризагызда үзегезне, матди хәлегез бик начар булу сәбәпле, уку өчен түләүдән азат итүләрен сорагансыз. «Туганнарым ягыннан ярдәм ала алмыйм, стипендия – минем өчен яшәвемнең бердәнбер чарасы», – дип язгансыз. Үзем дә 1950 елда студент булганлыктан, туганнарыннан ярдәм ала алмаучыларның ничек интеккәннәрен беләидем.

Беренче курсны тәмамлый алмагансыз, 2нче семестрда, укуга йөрмәвегез аркасында университеттан чыгарылгансыз. Соңрак Сез университеттан авыруыгыз аркасында китүегез турында язгансыз, аннары башка сәбәпләр дә күрсәтелә. 1949 елның 14 июнендә сорау алган вакытта Сез ТАССР Дәүләт иминлеге министрлыгы оперуполномоченные лейтенант Михеевка университетның тулай торагында (Чернышевский (хәзерге Кремль) урамы, 4 нче йорт) егерме студент бер бүлмәдә яшәгәнегез турында сөйләгәнсез. Алар

арасында күп укыган, белдекле студент, филолог Александр Кузнецов аерылып торган. Ул – дини эчтәлекле шигырьләр, ә Сез лирик шигырьләр язу белән мавыккансыз. Ул Сезгә Мережковскийны һәм башка ярым тыелган әсәрләрне укырга киңәш иткән. Сез аның йогынтысында булуыгызны, икәүләп, университетны ташлап чыгарга теләвегезне әйткәнсез. Чөнки, уку кешеләрнең тормышын яхшырта алмый, дип уйлагансыз. Сез, өегезгә кайтып, бераз уйланып йөргәннән соң, 1947 елның апреленнән Зәй комсомол райкомында кадрлар һәм оештыру бүлеге мөдире булып эшли башлагансыз. Шул чорда авылларга демобилизацияләнгән солдатлар кайта башлый, Сез бигрәк тә Гурий Тавлин белән дуслашып киткәнсез. Ул исә сугыш елларында Көнчыгыш Европа илләрендә булган, андагы крестьяннарның безнекеләргә караганда яхшырак яшәгәнлекләрен күреп кайткан.

1954 елның 8 сентябрендә сорау алу вакытында Сез Тавлин армиядән кайткан чорда чит илләрдәге тормыш турында бернәрсә дә белмәвегез, әмма ул сөйләгәннәр белән килешүегез турында әйткәнсез, ләкин ул да, Сез дә хакимият белән көрәшергә беркайчан да өндәмәвегезне искәрткәнсез. Шулай да һәр икегезнең дә авыр тормыш шартларыннан канәгать булмавыгызны раслагансыз.

1948 елда Сез университетка яңадан керү өчен гариза биргәнсез һәм шул ук факультетның беренче курсына кабул ителгәнсез. Бик яхшы укыгансыз. 1949 елның 16 сентябрендә ректор исеменә гаризагызда, барлык фәннәрдән дә «бик яхшы» билгеләренә укуыгызны күрсәтеп, үзегезгә югары стипендия билгеләүләрен сорагансыз. Сезгә югары стипендия биргәннәр, әмма икенче курсны укып бетерә алмагансыз, 1950 елның 7 апрелендә шул ук «дәресләргә йөрмәгән өчен» дигән билгеләмә белән янә университеттан чыгарылгансыз. Бер яктан караганда, бу – чыннан да шулай: Сез, дөрестән дә, укырга йөрми башлагансыз, әмма моның сәбәбе Сезнең язмышыгыздагы фаҗигале борылыш аркасында килеп чыга.

Сезнең 25363 нче тикшерү «эше»гез меңнәрчә шундый ук «эш»ләрдән аерылып тормый. Шул ук кат-кат сорау алу беркетмәләре, үзегез шикелле үк бичаралар белән күзгә-күз очраштырулар, гадел хөкемгә ышаныч, бу хәлләр тиздән бет-

сен дип, күрсәтелгән гаепләүләр белән килешү... Башыннан ахырына кадәр оештырылган бу провокацион гаепләүләргә дучар булучылар, башкарган гамәлләрендә бернинди җинаять составы да булмау сәбәпле, күптән акланган инде. Аларны совет хакимияте исеменнән хөкем иткәннәр, соңыннан шул ук хакимият бу гаепләүләрнең, «вакыйгаларның яңача ачылуы сәбәпле», хата икәнлеген таныган. Бернинди дә «яңача ачылган вакыйгалар» булмаган, хакимият кенә алышынган, гаепсезләрне ГУЛАГтан азат итү чоры башланган... Акланганнарның күбесенең язмышы сындырылган, аларны, бер гаепсез килеш, ни өчен соң «адәм актыклары», «җәмгыятьнең төшеп калган мәхлуклары» дип санаганнар? Ни кызганыч, аларның кайберләре, үз язмышларын кешелексез, тоталитар режим сындырганлыгын аңларга теләмичә, бер-берләрен гаепли башлый, бәхетсезлеккә дучар ителгән үз иптәшләрен әхлакый-мораль яктан гаепләүне таләп итә.

Немец философы Георг Гегель «чынбарлыкта булган һәрнәрсә акыллы» дигән. Кемнәр өчен акыллы? Көчләү-ирексезләүне, дәүләт террорын, хакимиятне үз кулларында саклап калу өчен үз халкын идеологик яктан аңгырайтуны хуп күргән партия-совет хакимияте өченме? Ә бу террорның миллионнарча корбаннарына нәрсә кала? Ул чордагы эзәрлекләү-репрессияләр беркемне дә аяп тормаган бит. 1953 елда ГУЛАГта өч миллионнан артык тоткын булган, шуларның өчтән бере чамасы үзләре кылмаган «сәяси җинаятьләр» өчен хөкем ителгән. Алар арасында төрле милләт кешеләре, шул исәптән меңләгән татарлар да булган.

Сәяси эзәрлекләү корбаннарын аклау комиссиясендә эшләгәндә, мин йөзләрчә «эш» белән таныштым, күпләрнең тикшерү-сорау алу вакытында физик һәм психологик газаплаулардан ничек тә булса котылырга, исән калырга омтылганын аңладым. Шуның өчен генә булса да алар кылмаган гамәлләрен дә таныганнар, тикшерүче алдан әзерләп куйган сорау алу беркетмәләренә кул куйганнар, киләчәктә хезмәттәшлек итәргә ризалык биргәннәр. Бары тик бик азлары гына тикшерүченең «вербовкага бирелми» дигән нәтиҗәсенә ирешкән. Соңрак алар, аклау чорында, кагыйдә буларак,

үзләренең башта сөйләгән сүзләреннән ваз кичкәннәр, тикшерүченең бик каты басым ясавын әйткәннәр.

Сезнең һәм иптәшләрегезнең эшләре белән танышканда, миндә, сез барыгыз да бер тикшерү провокациясе корбаннары булгансыз, дигән тәэсир калды. Хәер, һәммәсен дә тәртип белән сөйлик әле. Сез 1950 елның 20 мартында кулга алынгансыз. Сезне лейтенант Михеев кулга алган. Ул һәм аның ярдәмчесе Сез яшәгән Бехтеров урамы 15 нче йорт 7 нче квартирда тентү үткәргәннәр. Тентү вакытында, пүнәтәй сыйфатында, Сезнең белән бергә яшәгән курсташыгыз Нил Юзиев карап торган. Аңа Сезнең студент китапханәгездәге 47 китапны сакларга дип тапшырганнар.

Сездән элек тә сорау алганнар. Башта мин Сезне җирле чекистлар аерым шик астында тотмаганнардыр, аларны күбрәк Сезнең сабакташларыгыз, инде сугышны кичергән, күпне күргән өлкәнрәк иптәшләрегез кызыксындыргандыр, дип уйлаган идем. Янәсе, алар мавыгучан, хыялга бай, кызыксынучан яшь егеттән башка студентлар турында мәгълүмат алырга теләгәннәр. Әмма Сезнең белән бергә «Советка каршы агитациядә» гаепләнеп кулга алынган Г. Тавлин белән М. Рәфыйковның тикшерү «эш»ләре белән танышкач, Сезне кулга алу аларны кулга алуга караганда җентекләбрәк әзерләнгәнен аңлагач, ул фикеремнән кире кайттым. Чекистларның төп максаты, әлеге «чекист операциясе»нең үзәге — Сез икәнлеккә инандым.

Казандагы татар студентлары арасыннан «Советка каршы оешма эзләп табу» чекистлар өчен гадәти һәм күнегелгән бер эш булган, күрәсең: алар булачак корбаннарын чакыртып алганнар да хезмәттәшлек итәргә, «операция»гә катнашырга тәкъдим ясаганнар — Советка каршы сөйләгез, ә аннары әңгәмәдәшегезнең үзен ничек тотышы турында безгә хәбәр итәрсез, дигәннәр. Шулай тупланган компроматны аларның үзләрен үк кулга алганда гаепләү өчен кулланганнар. Тавлин белән Рәфыйков — сугыш кичергән кешеләр, ә Сез әле яшь, аларныкы кебек тормыш тәҗрибәгез дә юк, шуңа күрә бу «операция»не әзерләүчеләр сезне «эшкәртү» җиңелрәк, тиешле сорауларга җавап алу тизрәк булыр, дип уйлаганнардыр. Алдан ук әйтеп куям: Сезне һәм иптәшләрегезне «Со-

ветка каршы оешма» оештыруда гаепләп, Сезне шул оешманың башлыгы итәргә тырышулары барып чыкмаган.

Сезгә каршы компромат җыю планы инде 1949 елда ук гамәлгә ашырыла башлый. Сорау алу өчен Михеевка студентлар Наил Ганиев, Хәйбрахман Мөхәммәдиев, Бәһрам Хәйруллиннар чакыртыла. Алар 1945 елда сезнең белән бергә студентлар тулай торагында яшәгәннәр. Барысы да сезнең белән таныш икәнлекләрен әйткәннәр, әмма советка каршы шигырьләр укыганлыгыгызны хәтерләмәгәннәр. 1950 елның 23 гыйнварында Гурий Тавлин кулга алына. Икенче көнне сорау алу вакытында ул 1946 елда авылда Сезнең белән танышуы турында сөйли. Сезнең йогынтыгыз аркасында «советка каршы карашларыгызны» да уртаклаша башлавын әйтә.

Сезнең кулга алынуыгыз турыдан-туры тарих-филология факультетының өченче курс студенты Зөмәрә Тумашеваның[1] республика дәүләт иминлеге министрына язган гаризасына нигезләнгән булган. Ул болай дип белдергән: «ВЛКСМ әгъзасы һәм совет гражданкасы буларак, сезгә түбәндәгеләрне хәбәр итүне үземнең бурычым дип саныйм: 1948 елның көзендә мин КДУның 1 нче курс студенты Гыйләҗев Аяз белән таныштым. А. Гыйләҗев Казан педагогия студенты Г. Тавлин белән дус иде. Күптән түгел Гыйләҗев миңа Тавлин Г.ның дәүләт иминлеге органнары тарафыннан кулга алынганлыгын әйтте. 1 мартта Гыйләҗев бик борчулы иде, бу мине кызыксындырды. «Нәрсә булды?» – дип сорадым. Гыйләҗев шуннан аңа каядыр барырга кирәклеген әйтте. «Үземне энә өстендәге кебек хис итәм»,– диде. Мин моның Тавлин эше белән бәйле түгелме икәнлеген сорадым. Гыйләҗев раслап җавап бирде. Ниһаять, мине бер читкә алып китеп, Гыйлә-

[1] Аяз Гыйләҗев икенче мәртәбә университетка укырга кереп, беренче курста укып йөргән чагында, театр училищесы студенткасы Зөмәрә Тумашевага гашыйк була. Зөмәрә – Күчмә театр режиссёры булган Кәшифә Тумашева гаиләсендә үскән кыз. Аяз тоткынлык елларыннан соң Казанга кайтып урнашкач та, аның белән җылы мөнәсәбәттә булды. Ул аны ярата иде. Бервакытта да үзенең шикләнүләрен сиздермәде. Аяз: «Мине кем утыртса да утырткан инде, ул еллар корбаны булырга тиеш идем инде мин»,– дия иде. Ул беркайчан беркемгә рәнҗеп яшәмәде.– *Н. Гыйләҗева искәрмәсе*.

жев болай дип сөйләде: элек ул да Тавлин шикелле үк советка каршы кеше булган. Хәзер ул үзенең карашларын үзгәрткән, әмма элекке гаебе өчен авыр хак түләргә тиеш булачак икән: дәүләт иминлеге органнары аңа, советка каршы кеше булып кыланып, шпионнар оешмасын ачу бурычын йөкләгәннәр. Гыйләҗев миңа бу эшнең бик газаплы булуыннан зарланды, бөтен вакытын алуын әйтте, эшнең асылын белмәгән хәлдә, галәмәт зур механизмның бер шөребе кебек эшләргә туры киләчәк, диде. Бу эше өчен ул ышаныч та казана алмый, аз гына бүләк-фәләне дә тәтеми икән... Гыйләҗев үзе сөйләгәннәрне беркемгә дә әйтмәскә кушты, юкса конспирацияне бозган өчен аны каты җәза көтәчәк икән...»

Бу гариза бик тә әләккә, доноска охшаган. Ләкин бу очракта Сезнең ышанучанлыгыгыз гаҗәпләндерә, моны бары тик Сезнең гаҗизлегегез, гасабилануыгыз яки нишләргә белмәвегез белән генә аңлатып була. Ә бәлки... Сез, әлеге кыздан шикләнеп, аның карашлары үзгәргәнлеген хәбәр итүен теләгәнсездер? Моның урынына гаепләү маддәләрегез арткан гына: 58–10, 1нче өлеш – «советка каршы агитация» һәм 58–11 – «Советка каршы оешма төзергә ниятләү» дигән маддәләргә 121нче маддә – «ачарга тиеш булмаган мәгълүматларны ачу» дигәне дә өстәлгән.

Мәҗит Рәфыйков, Сез бер атна сак астында утыргач, 1950 елның мартында кулга алынган. Аннан алда, 28 мартта, Сездән, аның турында нәрсәләр беләсез, дип сораганнар. Сез таныш икәнлегегезне әйткәнсез, мөнәсәбәтләрегез «иптәшләрчә генә» икәнлеген, ике арада шәхси исәп-хисап юклыгын белдергәнсез. Сүзләрегезне раслап: «Рәфыйков үзен Ватанның чын патриоты итеп тотты һәм бертөрле дә советка каршы уйдырмалар сөйләмәде»,– дигәнсез. Соңрак Сез икегез дә тәнкыйть рухындагы бер сөйләшүегезне исегезгә төшергәнсез. Аны төрлечә шәрехләп булыр иде, әмма тикшерүче аңа гаепләүгә туры килә торган эчтәлек кенә салган. Сез, Рәфыйков белән студентларча гына тамак ялгап алгач, йөреп керергә чыккансыз. Әдәбият турында фикер алышкансыз, аннары Рәфыйков хан улы турында бер легенда сөйләгән. Хан үзенең улына алтын уклы җәя бүләк иткән, җәяне һәрвакыт – иңендә, укларны исә кында сакларга

кушкан. Әмма хан улы җәя белән укларны каядыр куйган да онытканнан. Исенә төшереп алып караса, җәя дә, кын да яраксызга әйләнгән, бары тик алтын уклар гына сакланып калганнар. Нәтиҗә шул: уклар белән җәя һәрвакыт янда булырга һәм халыкка кирәк чакта атарга тиеш. Сез шул чакта Рәфыйковка колхозчыларның авыр тормышы турында әйткәнсез һәм тук яшәү өчен, мөгаен, Америкадагы кебек фермерлар булу кирәктер, дигәнсез.

Рәфыйков сорау алулар вакытында үзен кискенрәк һәм ачыграк тота. Ул үзенең дәүләт иминлеге органнары белән 1944 елдан ук хезмәттәшлек итүен таный. 1950 елның 29 маенда сорау алганда, Сезнең белән лейтенант Михеев кушуы буенча танышканлыгын әйтә. Сезне Советка каршы сөйләшүләргә махсус котыртуын да яшерми. «Шул рәвешле,– ди ул,– Михеев өйрәткәнчә, 1949 елның ноябрендә Гыйләҗев белән сөйләшкәндә, мин үземне Советка каршы кеше итеп күрсәттем, аңа теләктәшлек белдердем һәм Гыйләҗевкә алга таба да Советка каршы сөйләшүләр өчен шартлар тудырдым». Кыскасы, ул яшь иптәшен һәртөрле котыртып тора.

Әлбәттә, ул чордагы сорау алу беркетмәләренә тәнкыйть белән карарга кирәк. Миңа тикшерүченең, гаепләнүчедән сорау алып та тормыйча, үз кулы белән тутырган беркетмәләре белән дә очрашырга туры килде. Еш кына тикшерүче, кулга алынган кешенең сөйләгәннәрен язып барганда, аның «бер танышым белән сөйләштем» дигән сүзләренә «Советка каршы сүзләр сөйләштек» дип өсти торган булган. Шулай да Сезнең эшегездәге беркетмәләрне һәм Тавлин, һәм Рәфыйковтан сорау алу беркетмәләрен укып, өйрәнеп чыккач, мин җиңел сулап куйдым: Сез үзегезне аларга карата гаделрәк һәм дөресрәк тоткансыз. Мин моңа игътибарны тагын шуның өчен юнәлтәм, 90нчы елларда алар тарафыннан Сезне, 1950 елда үзен лаеклы тотмады, дип гаепләү омтылышы да булды. Шул чагында Татарстан Язучылары берлеге идарәсе Рафаэль Мостафин җитәкчелегендә комиссия төзеде. Ул комиссия дә, мин караган материаллар белән танышып чыкканнан соң, «аларның бәхетсез язмышында Сезнең гаебегез юк» дигән нәтиҗәгә килде. Өчегез дә язучылар булып киткәнсез, ләкин Сез алар арасында талантлырак булгансыз.

1950 елның 28 октябрендә СССР Дәүләт иминлеге министрлыгы каршындагы Махсус киңәшмә Сезне «7 елга хезмәт белән төзәтү лагерена ябарга» дигән карар чыгара. 1950 елның 30 ноябрендә Сезне этап белән Казаннан Караганда өлкәсенең Долинское авылындагы 9нчы лагерьга озаталар. Ул лагерь (Карлаг) 1931 елдан 1959 елга кадәр эшли. Сез анда чагында, лагерь башлыклары полковниклар В. М. Маевский белән З. П. Волков була. 1951 елның гыйнварына лагерьда 45 675 тоткын булып, аларның яртысы диярлек сәяси маддәләр буенча хөкем ителгән. Тавлин белән Рәфыйковлар да лагерьга җибәреләләр.

Контрреволюцион җинаятьләре өчен хөкем ителеп, СССР Эчке эшләр министрлыгы лагерьларында, колонияләрендә, төрмәләрендә һәм сөргеннәрдә тотылган кешеләрнең эшләрен яңадан карау буенча Үзәк комиссиянең карары белән, 1955 елның 13 февралендә Сезнең эшегез туктатыла, һәм 1955 елның 6 июлендә Сез азат ителәсез. Шул вакытта ук Тавлин белән Рәфыйков та аклана һәм азат ителә.

Сез, туган якларга кайтып, Баграж авылы клубына мөдир булып урнашасыз. Шул ук вакытта үзегезне университетның тарих-филология факультетына читтән торып уку өчен 2нче курска кабул итүләрен үтенеп гариза бирәсез. 1956 елның февралендә, татар әдәбияты кафедрасы мөдире Х. Г. Госманов тәкъдиме белән, Сезне көндезгә укуга күчерәләр, отличник буларак, югары стипендия ала башлыйсыз, пенсионер улы булганга, уку өчен түләүдән дә азат итәләр. Ләкин бу юлы да университет студенты булып озак йөри алмыйсыз.

Профессиональ язучы булырга ниятләп, 1957 елда, өченче курста укуыгызны ташлап, «Чаян» журналы хезмәткәре булып урнашасыз. Ә инде алга таба, әдәби эшчәнлегегезгә киң юллар ачылып, сез 1961 елның сентябреннән ике елга Мәскәүгә Югары әдәби курсларга укырга китү бәхетенә ирешәсез. Югары курсларда уку еллары сезнең фикерләү сәләтегезнең офыкларын киңәйтте. Сез ул елларны гомерегезнең иң бәрәкәтле чоры итеп искә ала идегез.

Сез үзегезнең җәфа чигеп йөргән елларыгызны искә алырга яратмый идегез. Сезне һәрвакыт яңа сюжетлар кызыксындыра иде, моның матур бер нәтиҗәсе дүрт томлык

әсәрләрегез (Казан, 1993–1994) булды. Сез бик күп дәрәҗәле әдәби премияләр алдыгыз, пьесаларыгыз илнең күп кенә театрларында куелды. 1993 елда Сез Татарстан Республикасының халык язучысы исеменә лаек булдыгыз.

Сез 75 яшегездә, язучы, кеше һәм гражданин буларак, данызгызның иң югары ноктасында бу фани дөньядан китеп бардыгыз. 2002 елның 13 марты иде бу. Сез Тавлин белән Рәфыйковтан озаграк яшәдегез. 1990 еллардан килеп яңа меңьеллыкка аяк баса алган соңгы халык язучысы булдыгыз. Мин Сезнең белән соңгы тапкыр Сез инде каты авырган чакта сөйләшеп утырдым. Нәкыя Илһамовнаның, улларыгызның, оныкларыгызның нинди зур игътибар белән кайгыртуларын күрдем. Авыруыгыз Сезне төшенкелеккә салмады, Сез күтәренке күңелле булырга тырыштыгыз. Шулай да физик авыруыгыздан тыш Сезне илдәге вазгыять тә борчый, җәмгыятьнең Сез теләгәнчә үк булмавы кәефегезне кыра иде шикелле.

Ышаныгыз, бу хатны тәмамлавы бик кыен миңа. Без озак еллар бергә булдык, Сезгә беркайчан да җавап алынмаячак хат язарга туры килер дип кем уйлаган! Хәер, Аллаһының кодрәте киң, бәлки, төштә булса да, миңа Сездән хәбәр китерер әле...

*2007*

***Минтимер Шәймиев[1]***

## Сүзен кистереп әйтә белде[2]

Аяз Гыйләҗев – татарның әдәби мирасына зур өлеш керткән язучы.

Ул әдәбиятка аяк баскан еллар – каршылыклы фикерләрнең нык чәкәләшкән еллары булды. Әмма шундый фикер төрлелеге камалышында булган хәлдә ул үз сүзен кистереп әйтә белде. Мондый адымнар ясарга аны үзенең асылын-

[1] Минтимер Шәрип улы Шәймиев (1937) – дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе, Татарстан Республикасының беренче Президенты (1991–2010).

[2] Шәймиев М. Ш. Сүзен кистереп әйтә белде // Аяз Гыйләҗев: Истәлекләр / Төз. И. Гыйләҗев.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.– 2 б.

да тоткан юлының дөрес булуына ышанганлык кына этәрә алгандыр. Бу дөрестән дә шулай: «Өч аршын җир»ен алыргамы, яисә «Җомга көн, кич белән...», «Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», «Урамнар артында яшел болын», «Яра», «Йәгез, бер дога!» һ.б. әсәрләре – һәрберсе милләт, ил язмышына битараф булмаган оста каләм иясе кулы белән язылган хәзинәләребез. Аның публицистик язмалары, фәлсәфи фикерләре беркайчан да үзкыйммәтләрен югалтмаслар

1960–1990 елларда, татар театрлары сәхнәләрендә бер-бер артлы пьесаларын куйдыра торды. 1960 еллар башында аның щепкинчылар белән иҗат иткән «Көзге ачы җилләрдә» әсәре хәтердә уелып калган. Бу спектакльдә уйнаучы яшь артистлар сәхнәдә чирканчык кына түгел, үз-үзләренә ышаныч алдылар. Шуннан соң, эшләрен уңышлы дәвам итеп, щепкинчылар ярты гасыр дәвамында Г. Камал театрының төп көчләре булып, театр сәнгатебез үзәгендә иҗат итеп яшиләр.

Аяз Гыйләҗев – гомере буе профессионал язучы буларак иҗат иткән шәхес. Шулкадәр авыр язмыш кичергән кешегә ул елларда иҗат юлында зур каршылыклар булганлыгын без аның чордашлары буларак чамалый гына алабыз, билгеле. Үз каләм көченә ышанып, гаилә тоту аңа җиңел булмагандыр. Ничек кенә булмасын: ул нык куллы тирән фикер иясе, шәп гаилә башлыгы, оста художник булды.

Үзе Язучылар берлегендә җитәкчелек вазыйфаларын башкармаса да каләмдәшләре аның фикерләренә һәрвакыт колак салып тордылар, игътибарлы булдылар, исәпләштеләр.

Татарстанның халык язучысыАяз Гыйләҗевнең мирасын яратып һәм хөрмәт итеп яшәсәк, рухи офыкларыбыз киңәер.

*2006*

*Марсель Галиев*

## Оҗмах бакчалары хозуры[1]

*(Очерк)*

Ниһаять, миңа борынгы аргонавтлар йөзгән Урта диңгез дулкыннарына колач салу 1981 елның май аенда насыйп булды. РСФСР Язучылар берлеге оештырган туристик сәяхәт өчен хәләл акчамны түләгәч, уннарча кәгазь-белешмәләр тутырып, хәтта әткәң-әнкәң исән түгел икән, аларның кабере кайда икәнлегенә хәтле күрсәткәч... Бауман райкомының иркен кабинетында, биниһая озын өстәл тирәли утырган, корыч салкыны бөркелеп торган партия чиновниклары һәм өлкәннәр советы әгъзалары каршына бастырып, сине рентген нурлары аша үткәрәләр. Төрле сораулар биреп, капиталистик илләргә карата бик үк мәрхәмәтле караштa тормавыңа тәмам инангач кына, хәерле юл теләп, сине чыгарып җибәрәләр.

Шулай итеп, Казаннан без өчәү – Аяз ага Гыйләҗев, хатыны Нәкыя апа һәм мин – Испаниягә баручылар төркеменә эләктек. Калган язучы-галимнәр Мәскәү һәм Ленинградтан иде. Исеме таныш язучылардан тыш монда Бонч-Бруевичның оныгы, Ярослав Смеляковның хатыны, Максим Горькийның җиде яшенә кадәр Соррентода үскән оныгы Нина Пешкова да бар иде...

Искә төшсә, хәзер дә чирканып куям. Ширәмәт (2) аэропортында «чик»не узганда, ян-яклары тоташ пыяладан торган бәләкәй генә камерага килеп керәсең. Борын астына мыек та чыкмаган яшь солдат документларыңны ала да, пыяла аша, салкын күзләрен төбәп, гәүдәңне кадаклап куя. Бөтен күңелеңне актарып чыгарырлык итеп, керфек тә какмыйча үтәли тишеп карарга кайда өйрәткәннәр, нинди яшерен мәктәптә укытканнар бу империя солдафонын? Яшь кенә бит югыйсә, ә күзләре коточкыч җансыз, ник бер саплам нур әсәре булсын. Әмер генә бирелсен, әнкәсенә дә төбәп атачак бу! Өшеткеч караш вакыт-вакыт өскә төбәлә (чыгышлый күреп алдым, түшәм белән арткы стена тоташкан урынга

[1] Галиев М. Әсәрләр 6 т.– 5 т.– Казан: «Идел-Пресс», 2011.– 142–143, 147–148, 150–151, 178–179, 183–184 б.

кыеклап күзгә куелган икән), арт чүмечемнән нәрсә эзли бу истукан?!

Әлеге кабинада алган тискәре нурланыштан мин самолетыбыз һавага күтәрелгәч кенә арынып, тынычлана алдым бугай...

Салон буйлап эреле-ваклы шешәләрдә затлы эчемлекләр, сигаретлар, шоколадлар, тагын әллә нинди ялтыр каплар тезелгән нәни арбаларны этеп йөртәләр. Бар да – долларга. Бу нигъмәт-байлыклар безгә төс түгел икән. Алыштырырга рөхсәт ителгән 35әр тәңкә фәкыйрь акчаларыбыз җитәкче кулында, доллар хәлендә. Мадридта испан акчасы песетага алыштыргач кына ул аны безгә таратачак. Кесәдә акчаң булып, әйбер алалмау түбәнчелегенә инде күнегеп беткән идек, сыгылып торган байлыкка карап акчасыз тору да – шундый ук мескенлек икән...

Аэрофлот компаниясенең затлы ризыкларын шәраб белән сипләп куйганнан соң озак та үтмәде, самолетыбыз Люксембург аэропортына төшеп утырды. Монда алай документлар тикшереп мәрәкә килмәделәр. Вокзалга кергәч, тар гына аралыктан үтәсең, кырыйда полисмен карап-күзәтеп тора. Менә без, унлап кеше, тоткарлыксыз гына үтеп чыктык. Аяз ага килеп кергәч, полисмен кинәт калкынып килде дә, ике учына да ниндидер прибор кигән куллары белән Аяз аганың гәүдәсен баштанаяк сыпырып төшерде, аннары гына үткәреп җибәрде. Бераз каушап калган Аяз ага, аптыраулы елмаеп:

– Минем тюремщик икәнне монда да белделәр, слушайпарин,– дип куйды.

– Жан-Вольжан икәнеңне беләләр, Аяз ага.

– Шулайдыр. Тимер рәшәткә шәүләләре күзләрдә мәңгегә калалар. Күр инде, бүтән берәүне дә тикшерми бит... Киттек, әнә тегендә безнекеләр бушка гына капиталист сырасы эчәләр түгелме!

Озын стаканнарда сыра бирделәр. Ул дәвердә чит ил сырасын киноларда гына күрә идек. Менә хәзер эчәргә дә насып булды.

– Минем сырага ис китми. Йә, ничек, шәпме? – дип, Аяз ага гәрәбә кебек сыралы стаканны күзлегенә якын китереп карый.

– Артык юка боларның сырасы. Безнеке бит закускасы да үзендә була...

Иллюминаторга маңгаемны терәп, уйланып барам. Әх, Люксембург, Люксембург, аз гына көнчыгыштарак урнашкан булсаң, яшәтерләр иде сине аерым ил итеп, хәзергечә әйтсәк: «...в составе России...»

***

...Шул хәлләрне искә төшергән уңайдан мин, Аяз аганы читкәрәк алып китеп, рус холкы турында каяндыр ишеткән гаҗәеп бер анекдот сөйлим. Син дә тыңла, Гибралтар җиле, тыңла да дөньяга тарат...

«...Аллаһ катына бик күп халыклардан вәкилләр килгән, имеш, һәрберсенең үз гозере, үз борчуы... Әйтик, яһүд бөтен яһүди халкына җәннәти тормыш бирүне сорый. Татар, хәвеф-хәтәрсез сәүдәгәрлек итәргә мөмкинлек бирелсә, дөнья базарларын товар белән тәэмин итәр идем, барча халыклар да әйбәт яшәр иде, ди.

Аллаһы Тәгалә боларның теләген канәгатьләндереп җибәрә тора, шулай итеп, руска чират җитә:

– О господи! – ди рус, гөнҗәлә сакалын сыпырып.– У моего соседа Степана есть две коровы, у меня же ни одной. Сделай так, чтобы и у соседа не было коровы...»

Аяз ага, анекдотны ошатып, ялкау гына көлеп куйды. Сизеп торам, аңа да рәхәт: аяз күк, саф һава, кояшлы Гибралтар җиле, тән-аң изри – яшисе килә!

Югыйсә Аяз аганы бер кыздырып җибәрсәңме – чыдап кына тор: куллары канат булып калкына, кыска тәпиләре белән ярсып-ярсып йөренә, күзлек ырмавы астыннан борыны ыргып күтәрелә, катлы-катлы сүгенү белән утлы сүзләрне аралаштырып сибә генә! Андый чакта Аяз аганы беркем дә бүлдерә алмый, үз-үзен ыргытып сүккән утлы йомгак каршында озын буйлы кеше дә күз алдында кечерәя бара. Аннары бөтен гарасатлы ялкынын сибеп бетергән Аяз ага кинәт туктап кала, төтене генә калган корбанының күләгәсен тап-тап, бөтенләй юк итеп китеп бара. Нәсел-нәсәбе актарылып чыккан, мәңге кичермәслек сүзләр әйтелгән кеше, берничә көннән соң гына айнып, тормышка кайта. Икенче вакыт ка-

рыйсың, Аяз ага теге кешене кочаклаган, күкләргә чөеп мактый: сүккән чактагы «бездарь... доносчы... надан... мокыт...» дигән эпитетлар урынына «чорыбызның акыллысы... талант иясе! Бөегебез!..» дигән саллы сүзләр сибелә. Күпләр белә: Аяз ага кемнедер күкләргә чөеп мактый икән, димәк, көт тә тор, бераздан салып таптаячак. Ә кемнедер юк итә икән, димәк, күпмедер вакыттан соң ул аны җирдән күтәреп алып, тузанын кагачак... Нишлисең, Аяз аганың сөргендә чарланган холкы шундый, безгә аны башкача кабул итү мөмкинлеге бирелмәгән...

***

Еллар үткәч, үземне изалап, борчып йөргән сорауны мин, сынап карар өчен, Аяз агага бирдем:

– Алласыз һәм тарихсыз проза вәкиле булу Сезне куркытмыймы?

Аяз ага соравымны тарайтыбрак кабул итте. Мин һәркем тарихи әсәрләр язарга тотынырга тиеш дип санамыйм. Аннары... большевиклар һәр үткән көнгә тарихи дип мөһер сугарга безне күнектереп бетерделәр. Чын тарихның кан тибешеерактарак, тирәндәрәк бугай шул...

Хикмәт башкада... Татар сандугачы белән испан сандугачының сайравында аерма бар. Берсе – зәйтүн куаклары аша, икенчесе таллар аша ишетелә.

Ерак бабаңның яуда кылыч очы яралаган урыны синең тәнеңдә вакыт-вакыт сулкылдап куямы?

Догасыз булсаң да, бер-бер гөнаһ кылыр алдыннан күңелеңдәге үз аллаң кулыңнан тотамы һәм син, оялып, күккә багасыңмы?

Юк, мин Аллага табыну, тарихны турыдан-туры язу хакында әйтмим, һәр сүз сөрешендә, һәр сурәтләүдә тарих дымын, тарих исен-төсен сирпелдереп, Күк һәм Җир арасында мәртәбәле гасырлар кичкән олуг тарихлы халыкның тарихлы улы булу хакында иде сүз...

***

Менә без Мадридның Испания мәйданында Сервантеска куелган мәһабәт һәйкәл янында басып торабыз. Мигель де

Сааведра Сервантес – испан милләтенең йөзек кашы, һәйкәле дә әнә ничек сәнгатьле итеп куелган. Гасырлар кичеп тә үткенлеген җуймаган кешелек романы язган әдип биектә уйланып утыра. Астарак каһарманнары: Дон Кихот – атта, Санчо Панса ишәккә атланганнар. Боларны язучы уйлап чыгарган, тормышта булмаган, дип, испан халкын ышандырып кара хәзер.

– Бездә мондый һәйкәл куела алмый,– дигән идем, Аяз ага, кызып, фикерләрен актарып ташлады:

– Романнардан үз аягы белән чыгып, халык күңеленә күчкән геройларыбыз кая? Шерлок Холмс, Квазимодо, Обломов кебек геройларыбыз бармы? Без бит, үзебез тудырудан битәр, тормышта яшәп киткән әзер геройлар итәгенә тотынып язарга яратабыз!

Кичкырын, кунакханәгә кайтып барганда, Аяз ага сабырсалмак кына янә шул хакта сүз башлады:

– Сервантес туганга да дүрт йөз елдан артып киткән бит инде. Испаннар өчен – җиңүләр гасыры, ә безнең коллыкка төшү дәверләре. Латин Америкасының унтугыз иленә рәсми испан телен таккан милләт булыр ул... Әдәбияты да – карт, олпат әдәбият. Аларны куып җитү өчен безнең запаста тагын өч йөз ел бар әле... Шаяртам, әлбәттә. Безгә ашыгырга кирәк. Дөнья халыклары арасында билгесез булып, тапталып калмас өчен! Әгәр без бер телле, оешкан, бердәм милләт булсак, күптән инде... Карамзиннар, Державиннар, Купринnарыбыз, читкә китмичә, үзебездән калыккан булыр иде...

***

Кайчандыр гарәпләр Мансанарес елгасы буенда Мәҗирит кальгасы төзегән булганнар. 1083 елда бу кальга испаннар тарафыннан яулап алына, һәм шул урында Мадрид каласы төзелә башлый. Менә шул озын гомерле чал башкала белән танышуыбызның соңы да җитте. Кичен саубуллашу банкеты һотельнең ресторан залында булды.

Ашау-эчү, шау-шу. Каршыдагы телевизор экранында коррида бара. Йөз меңнәрчә кешелек стадион күз угын тореадорга, алтын белән чигелгән ыспай киемле мәйдан батырына төбәгән. Стадион гүли, үкерә, кайный. Мәрмәр маңгайлы

кара үгез аның саен ярсый, җитмәсә, бандерильеролар, аренага йөгереп чыгып, төсле тасмалы кечкенә сөңгеләрен үгез сыртына кадый торалар. Кан күреп акылдан шашкан стадион бер-берсен таптап, укмашып бетәр шикелле.

Коррида – испаннарның милли тамашасы, пар чыгару мәйданы. Революциягә кадәр Казанда руслар һәм татарлар Кабан күле бозында, йодрык сугышы оештырып, шулай «пар чыгара» торган булалар.

Аяз ага белән янәшә утырабыз. Мул яшелчәле ризык тәлинкәләре бер-бер артлы алышына тора. Менә мин гәрәбә кебек сап-сары дөге арасында яткан диңгез кабырчыкларын ачам да... эчендәге лайлага чәнечкемне батырырга чирканып торам. Аяз ага көлә, ашау ягына килгәндә ул – гурман. Ризык турында сөйли башласа, ашказаны бизләреңне котыртып тәкатьсез калдыра, баш миеңә кан йөгерергә мөмкин.

– Син аны, слушай-парин, тиз генә кабып йот та артыннан сыра эчеп куй. Устрица – деликатес, кайчан эләгә ул сиңа. Бәрәңге корсаклы илгә кайтасыңны онытма!...

***

– Хуш, Мадрид!

Оҗмах иле Испания, купшы агач-куакларың, кояш зурлык чәчкәләрең туйдырды, тизрәк кайтып, үзебезнең каен урманнарында, абагалар арасына чалкан төшеп, агач ябалдашларының күк йөзен назлы кытыклап талгын җилдән тибрәнгәнен күрәсе килә.

Ниһаять, төрле төстәге, төрле телдәге милләтләр букетын төягән «Боинг» самолеты испан күгенә күтәрелде. Иллюминатор кырыенда Нәкыя апа, уртада Аяз ага, кырыйда – мин, өч татар шулай янәшә урнаштык. Бераздан урындыкка беркетелгән өстәлләребезгә ризык китерделәр. Кара уылдыктан башлап шәрабка кадәр – бар да җитү.

Күңел – фәрештәләр катында. Көчле тәэсирләрдән вакыт төшенчәсе сузылган, өйдән чыгып киткәнебезгә еллар үткәндер кебек. Без әле Мадрид янындагы Америка хәрби базасыннан ниндидер хәтәр чир таралганын да, шуңа күрә безне Мәскәү аэропортында табиблар каршы алып, «чикне» дүрт-биш сәгать чыгармыйча тикшерәчәкләрен дә, үзәк ку-

накханә янында салкын күзле, шешенке чырайлы егетнең егерме тиен сорап-таләп итеп торачагын да, төнге унбердә буш ресторанга төшкәч, керләнгән җәймәле өстәлгә: «Менә шушы калды, ашагыз!» – дип, бройлер тавыкны лаҗырайтып ташлаган тәмсез телле ханымнан чирканып чыгып китәчәгебезне дә, «Йә Хода, кая кайттык без?!» дип, өметсез чынбарлыкка чарасыз кушылып китәсебезне дә уйламый идек әле. Кеше аңы тиз томалана икән, кайтып төшүебезгә бар да үзгәргәндер, якты чырайлы ил каршы алыр кебек иде югыйсә. Аннары... Тоталитар таш яңадан иңгә менеп кунаклар. Таныш таш... Безгә, башны горур чөеп йөрергә базмыйча, гомер буе шул ташны күтәреп йөрү хокукы бирелгән.

Самолет канаты астында – Альп кыялары, серле упкыннар.

– Слушай-парин, бу мизгелне бүтән кабатлап булмый, кабатлап булмый моны, әйдә, күтәрик әле шуның өчен! – дип, Аяз ага фужерын кулына ала. Чәкештерәбез. Икебезнең дә йөзләрдә – сәбәпсез елмаю...

Севильяда Аяз аганың миннән рәхәтләнеп, эчен тота-тота көлгәнен искә төшерәм. Мәйданда төрле илдән килгән йөзләрчә турист кайный, ә аяк киеме чистартучы малайлар, «шарманкаларын» асып, өерләре белән минем арттан йөриләр. Чебен куган кебек чәбәләнә-чәбәләнә чак котылам үзләреннән. Аяз ага көлеп рәхәт чигә:

– Сине яраттылар болар. Бөтен кешедә чүпрәк туфли. Күн туфли, җитмәсә, ясалма күннән – бөтен Испаниядә бер синдә генә. Интектермә, слушай-парин, эш бир малайларга!

Самолетта эчкән шәрабның тәме башка... фәрештәләр үрелеп кенә бармагын тыгып ала, күрәсең. Менә хәзер, хәмер канга тарала башлауга, үз чиратымда мин дә Аяз агадан көләргә илһам җыям...

– Дөньяның җиде могҗизасы бар, диләр бит әле, Аяз ага... Әйтик, Мисыр пирамидалары, Семирамиданың асылмалы бакчалары, Галикарнас мавзолее... Без күргән хисар, әмирләр сарае Әлһәмра...

– Ул сигезенче могҗиза була инде,– дип бүлдерә мине Аяз ага.

– Юк... Сезнең өчен – тугызынчысы, Аяз ага,– дигәч, аксакал, төшенеп бетмим, дигән шикелле, миңа карап куя.

– Сез бит, Аяз ага, «Зәй энҗеләре» дигән әсәрегездә, Зәйдә төзелеп яткан ГРЭСның төнге утларын күргәч, «менә ул дөньяның сигезенче могҗизасы» дип язгансыз...

Аяз ага сүрән генә көлеп куйды, ыргылып торган борын өстендәге күзлеген төзәтте, йөзенә кызгылт рәшә сирпелде.

– Безнең Урта Баграж авылында Пауыл дигән бер карт булган. Аны армиягә дә алмаганнар, авылдан бер яры да чыкмаган. Шуннан берзаман моны Чаллыга ияртеп алып баралар. Элеватор тавына менеп, бу Кама өстен күзәтә икән. Еракта – Алабуга, куе урманлы ярлар күренә. «Болар да безнең патшалыкмы?» – дип сорый икән бу. «Безнеке, безнеке...» – дигәннәр авылдашлар. «Билгән дә икән Рәчәй җирләрне!» – дип әйтә, ди Пауыл. Шуның кебек... Мин кайда, ни күргән ул чакта. Юньле-башлы ат та җигә алмаган кеше каршында йөзләрчә машиналар, меңнәрчә утлар пәйда булсын әле... Әйткәнмендер инде, «могҗиза», дип тә ычкындырганмындыр. Кемгәдер ярарга да тырышканмындыр, бәлки.

***

...Мадрид – Мәскәү самолеты, болытларны аралап, җиргә якыная. Гүя без еллар тавыннан төшеп киләбез. Аста урман-күлләр – сусыл яшеллек. Төсе ят чит ил туфрагыннан соң җанга якын манзара.

Тәгәрмәчләр җиргә тигән мизгел бөтен вөҗүдең аша үтә, исән-имин кайтып җиттек бит, дигән уй-шатлыгыңнан күңел мөлдерәп тула. Ул арада салон, тыйнак кына «Ура!» кычкырып, дәррәү кул чаба башлады. Матур булса да Испаниясе, һәркемнең үз Исламиясе...

Әнкәң кебек үк, туган илне дә сайлап алып булмый, ничек бар, шулай яратырга хөкем ителгәнсең. Кыйнап һәм кыйналып яратырга...

*1981–1997*

*Тәлгать Галиуллин*

## «Өч баһадир» һәм бер тәнкыйтче турында риваять»[1]

*(«Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы» роман-эсседан өзек)*

Кешенең үз гомере буена
Тапкан иң зур табышы –
Тугрылыклы дуслары.
*Каюм Насыйри*

Әле дә яхшы хәтерлим, 1994 елда татар матбугатында танылган фото остасы Мидхәт Шакирҗановның ифрат кызыклы бер рәсеме пәйда булды. Рус былина каһарманнарына охшатыпмы, әллә бездә дә хөрмәткә лаеклы олы шәхесләр бихисап, дип, бәхәсләшепме төшерелгән рәсем берничә ел дәвамында Татарстан Язучылар берлегенең болын чаклы кабул итү бүлмәсенең диварында эленеп торды. Астына «Өч баһадир» дип язылган сурәттә XX гасырның икенче яртысы татар прозасының, бу сүзне авыз тутырып әйтәм, бөекләре төшерелгән иде: Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев һәм Мөхәммәт Мәһдиев. Бу истәлекле рәсем язучыларның альбомнарында, аерым алганда М. Мәһдиевнең «Кеше китә – җыры кала» (1996) җыентыгында да урын ала. Буйга дусларыннан калкурак, гәүдәгә тулырак М. Мәһдиев, нәкъ рус халык иҗаты узаманы Илья Муромец кебек, уң кулын маңгаена куеп, әдәби офыкны күзәтә. Язучылар берлегендә булганда, шул фотога карап, сокланып, булган бит сүз сәнгатебезнең илаһи затлары, дип уйланып кайтучы бер мин генә булмаганмындыр. Баһадирларыбыз үз вакыты белән берәм-берәм мәңгелеккә күчкәч, бу рәсемне кемдер, ошатмыйча, дивардан алдыртты. Аның хәзер кая икәнлеге дә билгесез. Ник туганыңа үкенәсең килмәсә, керән кебек ачы, яхшы пычак кебек үткен телле Аяз әкә исән чакта кагылып кара идең бу рәсемгә. Үзе юкның – күзе юк, дигән шул халкыбыз.

«Ни өчен нәкъ шул каләм ияләре сынга алынып, «өч баһадир» дип аталганнар соң?» дигән соальнең тууы да табигый. «Талантлы язучылар» дип кенә котылыр идең, татар прозасы

[1] Галиуллин Т. Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы.– Казан: Татар.кит.нәшр., 2012.– 191 б.

бер чорда да талантларга кытлык кичермәде, җитмәсә әле татар хатыннары башка милләтләргә Чыңгыз Айтматов кебек даһиларны бүләк итте. Үткән гасырның икенче яртысында гына да Г. Бәширов, Ф. Хөсни, М. Әмир, Ә. Еники, И. Гази, А. Расих, И. Салахов кебек өлкәннәр ышыгында Н. Фәттах, Х. Камалов, Р. Төхфәтуллин, Х. Сарьян, М. Хәбибуллин, Ә. Баянов кебек теләсә кайсы алга киткән әдәбиятның йөзенә кызыллык китермәслек сүз осталары күтәрелә. Соңгылар белән бер чорда яисә үкчәләренә басып килгән М. Әмирханов, З. Зәйнуллин, А. Хәлим, Ф. Бәйрәмова, Ф. Садриев, М. Маликова, Р. Мөхәммәдиев, Ә. Гадел, М. Галиев, Ә. Гаффар, К. Кәримов, Ф. Яруллин, Р. Низами, Н. Әхмәдиев, З. Хөснияр, Р. Зәйдулла, Г. Гыйльманов, Р. Галиуллин һ.б. төрле буын сүз осталары хәзерге прозабызның горурлыгын тәшкил итәләр. Әдәбиятыбызны төптән тартып баручыларын гына саный китсәң дә, кул-аяк бармаклары җитми, энҗе-мәрҗәннәрдәй җемелдәп, үзләренә чакырып торган әсәрләрен уку рухыңны баета, татар халкының киләчәгенә өмет уята. Әле бит сүз сәнгатенең шигърият дигән илаһи төре, театр тоткан драматургиясе, вакыт-вакыт түрәләрне сискәндереп алган публицистикасы бар. Аларны да рәнҗетәсе килми.

Шулай да рәсемгә өч язучыбыз дөрес сайлап алынган дип саныйм.

Әдәби очрашуларда, кичәләрдә аларны – өч дусны – Г. Ахунов, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗевне – бергә еш күрергә мөмкин иде. Бу – табигый. Талант һәрвакыт үз ишенә тартыла. Алтмышынчы еллардан алып бу өч сүз остасы татар прозасының, өлешчә драматургиясенең дә, әйдәп баручы, йөзен билгеләүче язучылар буларак танылдылар. Ә инде И. Гази, М. Әмир, Г. Әпсәләмов, А. Расих, Ф. Хөсни кебек олы затларыбыз дөньяны ташлап киткәч, әдәбият дилбегәсе алар кулына күчә. Иҗатлары да, үзләре дә бер-берсенә охшамаган, әмма уртак максат, рухи бөеклеккә омтылыш, милләт киләчәге өчен җанатып яшәү каләм ияләрен якынлаштыра.

Үткән гасырның икенче яртысында татар әдәбиятында барган үзгәреш-яңарышлар, рухи дөньябызның яңа кыйтгаларына үтеп керүләр, татар милләтен үзаңлы, кабатланмас

үзенчәлекле, ямьле һәм мәгърур сыгылмалы телле, шуңарда мәңге яшәргә лаеклы халык буларак миллилекнең фәлсәфи расланышы нәкъ менә алар иҗатында тулы гәүдәләнешен тапты. Социалистик реализм методы тантана иткән чорда тәнкыйди реализмны яңа югарылыкта «терелтүчеләр», җан өрүчеләр нәкъ менә шул каләмдәшләребез, бигрәк тә Аяз Гыйләҗев белән Мөхәммәт Мәһдиев булды. Алар кальбеннән өзелеп төшкән роман-хикәяләр, бәян-драмалар, публицистик, тәнкыйди әсәрләр, истәлекләр, вакыт узган саен, яңа сыйфатлары, беренче танышуда күзгә бәрелеп тормаган гүзәллекләре, икенче, өченче мәгънәви тирәнлекләре белән ачыла баралар. Бу өч затны бер рәсемгә туплаган икенче сәбәп – аларның ихласи дуслыклары, дидек. Халкыбызның йөзек кашларыдай йөртелергә лаеклы ошбу шәхесләребез бер-берсенә таләпчән, иҗатларына нисбәтән кырыс та була белгән аркадашлар иде. Ягъни әлеге якынлыкның нигезендә әдәбият үсеше өчен җаваплылык, рухи теләктәшлек ятса да, алар буш ләббәйкә яудыру дәрәҗәсенә төшмичә, һәр яңа әсәргә (шул исәптән үз иҗат җимешләренә нисбәтән дә) сыйфатына карап, бәя бирергә тырыштылар.

Миңа алар өчесе бергә туры килгән очракларда юлдаш булгаларга туры килде. Бу хакта язып чыкканым да булды. Гадәти, шул ук вакытта мәгънәле, дустанә һәм кинаяле сөйләшүләр, башкалар өчен сәеррәк тоелырга мөмкин булган төрттерүләр. Аларны якыннан белмәгән кеше берни аңламый. Менә алар, җилкәләрен «чәкештереп», мәҗлестә утыралар.

– Гарифҗан, бер пирог кисәген алып бирче, синә тарелка якын.

– Шаяртма, парин, анысы минем өчен артык зур. Хәзрәт малаена, Мәһдигә калдыр.

Мөхәммәт ишетеп ала.

– Егетләр, мин – язучылар арасында иң аз ашаучы. Халык белә. Гариф, мине кочкан булып, пиджакка кулларыңны сылама әле, зинһар.

Аларны районга чакыралар. Дирижер – Ахунов. Дусларына телефон аша ым сала.

– Сабага дәшәләр. Әллә чыгып, укучылар белән аралашып алабызмы?

– Шаһидә сине җибәрәме соң, Гарифҗан?

– Син, абзый, Нәкыяң белән сөйләш, Шаһидә апагызны көйләүне-җайлауны үз өстемә алам. Бер-ике көн салпы ягына салам кыстырсаң, юлга бер коньяк та төреп тыгар әле. Минем Шаһидә алай кысмырлардан түгел.

– Анысы ук булмас, парин, шыттырма!

– Аяз, «Яра» повестеңны сөреп чыктым. Мавыгып китеп, сәгать икедә генә ятылган. Яхшы әсәр язгансың, рәхмәт. Миңа «Өч аршын җир»ең күбрәк ошый. Монысына психологик эчтәлек җитеп бетмиме шунда, әллә мифологик фикерләүгә өстенлек бирәсеңме, өздереп әйтә алмыйм.

– Парин, син дә хаклысың, һәр елны бер үк дәрәҗәдәге әсәр биреп булмый икән. Мәһди каядыр ашыга. Язып бетерәсе әйбере бардыр әле. Һәр елны бер повесть, йә роман биреп бара. Берсеннән-берсе затлы әсәрләр.

– Син, Аяз, Мәһдине тоташ мәдхиягә чумдырып аздырма. Аңа да әйтәсе теләкләрем бар.

Үзара очрашканда, төрттерү, үртәшү-көлешү, сүз белән чеметеп алу җитәрлек була иде. Ике яклы пычак кебек үткен телле А. Гыйләҗев:

– Мөхәммәт, дөресен әйт әле, синең әтиең, урыны оҗмах түрендә булсын, чыннан да мулла идеме?

Тегесе, мәкерне аңламыйча:

– Ни өчен сорыйсың? Шикләнергә нигез бармы әллә?

– Бар шул, парин. Характерың йомшаграк. Мәәзин малаена охшабрак торасың.

– Мин сезнең белән генә шулай, кырыс таләпчәнлегем турында студентларымнан сора,– дигән җавап белән генә дусты Аяздан котылып булмасын чамалаган Мөхәммәт «ва банк» бара. – Мин бит явызлыкка Караганда шахтасында өйрәнеп кайтмадым. Мин – куркытылган нәсел баласы.

Шуннан соң инде икәүләшеп Ахуновка «күчәләр».

– Гариф, син ар телен беләсеңме? – ди Аяз әкә.

– Белмим. Миңа удмурт теле ни пычагыма кирәк?

– Әдәбиятларының классигы булып, түрдә генә утырыр идең,– дип өсти Мөхәммәт.

– Килеш-килбәтең, йөреш-гадәтең белән син койган да куйган удмурт инде,– ди «Өч аршын җир» авторы.

– Ярый, күпсенмәгез. Бөек татар әдәбияты классигы булып йөрим әле,– ди Ахунов, сүзгә кесәгә кереп тормыйча.

Таныш-белешләре, якыннары күп булса да, ахыргача ачылып китә, серләрен уртаклаша торган дуслары күп түгел иде «өч баһадир»ның, талант талантка тартылу өстенә, рухи якынлык аларны берләштерә. Ә инде әдәби мәйданда алар рухына туры килмәгән, тәртәгә тибә торган берәр зат килеп чыкса (мәсәлән, Ф. Мусин А. Гыйләҗев әсәрләренә берьяклырак бәя бирде), «тегене» урынына утыртуда бердәмлек үрнәге күрсәтә белделәр. М. Мәһдиевнең иҗат юнәлешен иң тирән аңлап, татар сүз сәнгатенә алып килгән яңачалыгын ачкан мәкаләләр А. Гыйләҗев («Сайланып чыккан сүзләр») һәм Г. Ахунов («Авыл пәйгамбәре») каләмнәреннән төште.

Прозабыз баһадирларын якынлаштырган, анысы инде үзләреннән тормаган, тагын бер тарихи сәбәп бар иде. Өчесе дә – тоталитар режим камчысын, изүен татыган шәхесләр. Ачлыктан үлем хәленә җиткән гаиләсен саклап калу өчен, бер күтәрәм бәрәңге урлап, Гариф Ахунов төрмәдә утырып чыга. Үз башыннан узган хәлләрне тасвирлаган «Йәгез, бер дога» авторы кызлар култыклап йөрисе биш елын Караганда якларында уздыруга мәҗбүр ителә. Мөхәммәтне «сатлык җан баласы» исеме гомер буена диярлек эзәрлекли.

Миңа алар белән 1994 елның көзендә Питрәч районының Күн авылында еллык урып-җыюны тәмамлау бәйрәмендә катнашырга насыйп булды. Көннең бик яңгырлы, салкынча булуына карамастан, олуг затларыбыз белән аралашу үзе бер бәхет иде. Бу сәфәр турында «Өлкәннәр» исемле язмамны да бастырган идем. Шуннан соң унбиш елга якын вакыт узган булса да, кире кайтарып булмаслык ул көннәр һаман күз алдында. Ник дип әле шул очрашу-аралашу вакытында игътибарлырак булынмаган, яшәешебез кыйбласы, татар милләтенең кабатланмас үзенчәлекләре, әдәби барышыбызга, аның аерым шәхесләренә бәяләре турында сораштырмадым икән дип, үкенеп утырган чакларым аз булмады. Инде өчесе дә – оҗмах кошлары. Мөхәммәт 1995 елда кинәт китеп барды. Кешенең гомере, халык җырындагыча әйтсәк, һай,

бик кыска шул. Әнә кара каргаларның 250 ел яшәгәннәре дә бар, диләр. Әле шул кыска гына тормыш аралыгында Ходай Тәгалә адәм баласына бихисап сынаулар җибәрә.

Мин бу шәхесләрнең өчесе белән дә булсын – «Казан утлары»ның редколлегия утырышында, булсын – кабул итү коллегиясендә, гел аралашып, фикерләшеп яшәдем. Рәсми сөйләшүләр беткәч тә, гадәттә өч дус өйләренә ашыкмыйлар. Гариф абый кемгәдер телефоннан чылтырата, А. Гыйләҗев бүлмәдәге китапларның тышлыгын өйрәнә, Мөхәммәт, бүреген угалап, кара кыска мутон тунының кесәсенә кулын тыгып, тәрәзәдән карап торган булып, баш мөхәррир Равил Фәйзуллиннан тәкъдим көтә.

– Абзыйлар, ашыкмагыз әле! Берәр чынаяк чәй эчеп алырбыз. Сөйләшеп тә бетермәдек кебек әле.

Бүлмә хуҗасының ымын көткән «абзыйлар» шул мизгелдә үк туарылып китеп, портфельләренә үреләләр. Тиз арада өстәл шоколад, чикләвек, су, коньяк ише ир-ат ризыгы белән бизәлә.

Бүлмә хуҗасын кара ялтыравык өстәленең чиста калуы борчый, аңа тап төшеп, матурлыгы бозылмасын! Ник дисәң, редколлегия әгъзалары аңа газиз терсәкләрен терәп куеп, татар әдәбиятының сыйфатын, киләчәген билгелиләр. Һәркайсыбызның алдына чиста кәгазь, плакат, үткән елгы календарь ише әйберләр җәелә. Аз-маз капкалап, тамак кытыгын бастырып алганнан соң, китә протоколсыз аралашу, сөйләшү; фикер алышуның киңлеге галәм чикләренә дә сыймас дәрәҗәгә җитә.

Шул чорда вак-төяк күренгән сөйләшүләр, бер-берсенә теләкләр теләүләрдән алган тәэсирләр озак саклана, истәлек булып күңелдә яши. Шул мизгелдә әйтелгән фикерләр мәңгегә күңелдә калыр дип инансаң да, кеше хәтере бар нәрсәне саклый алмый шул. Язын мәңге яшелләнеп торырдай яфраклар көзен шыбырдап коелган шикелле, бик мәгънәле сүзләр, фикерләр төшеп кала икән.

Сүзне, гадәттә әүвәл рәсми кеше буларак, соңрак «йогып» калган гадәт буенча, «мин болайрак уйлыйм» дип, Гариф абый башлап җибәрә, Мөхәммәт белән мин дәвам иттерәбез, аннан инде дилбегәне кулына алып, авызыннан саесканны

Аяз абый очыра, сүзне «Өч аршын җир», «Җомга көн, кич белән...», «Яра», «Әтәч менгән читәнгә» кебек укыла торган әсәрләренең туу, язылу, басылу, бәя алу тарихыннан башлап, яшь чактагы егетлекләренә чаклы барып җитә. Сөйләүченең, берәр чәркә капкач, арттырып, камырга чүпрәне өсти торып, күпертеп сөйләргә яратканын барыбыз да яхшы беләбез, шуңа күрә аның берише бәяннарын халык иҗаты үрнәге кебек, елмаеп-көлеп, «алай ук булмагандыр», «бераз арттырасыңдыр» кебек шик белдергәндәй башларны селкеп, нотыкчыны кыздырып, канына тоз сибеп утырабыз.

Арабызда барыбыздан да, миннән дә яшь, Иделне аркылыга йөзеп чыккан, шигыренә дә, яшәешенә дә узышчы холкы салынган Равилнең утырганын онытабыз. «Әйдәгез, теләгәнчә шыттырыгыз, абзыйлар, бу өстәл янында демократия», – ди иде кебек аның күз уйнатуы. Күпертүләр гиперболага юл бирә башлагач, аның да тәкате корый.

– Аяз абый, бер үк вакытта өч гүзәл кыз артымнан бәйләнеп йөрде, дип, арттырасыңдыр инде.

Сөйләүче, бүлмә хуҗасының сүзен бүлдерүенә исе китмичә, борын очына якынлашып килгән күзлеген күтәребрәк куя да:

– Соң, парин, без монда ни өчен җыелдык соң? Бераз өстәп күңелне күтәрмәгәч тә. Бу хәл минем белән булмаса, берәр каһарманым шундый бәхеткә тарган булырга мөмкин.

Шул рәвешле, елына бер яки ике була торган мондый очрашуларның «гаепле» кешесе талантларны таный, өлкәннәрне олылый белгән, күренекле шагыйрь, «Казан утлары»ның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, дигән идек. Аяз әкәнең сөйләшүләргә юнәлеш бирүчән теле, Мәһдиевнең йомшакка утырткан булып катыга төшерүе, Ахуновның, урыннан сикереп торып, як-якка сибелгән чәчләрен тәртипкә чакырып чәчрәп чыгуы, бүгенгедәй күз алдында. Шул очрашулар барышында бер-беребезне аңлап, күктән эзләгәнне җирдән таптык. Тыштан караганда, безнең арада уртак нокталар да юк кебек. Равилнең бөтен барлыгын «шигырь җене» биләгән, мин шагыйрьләр иҗаты белән мәш киләм, публицистика белән шөгыльләнәм, алар исә татар прозасының умыртка

баганасын тәшкил итәләр. Мәгәр тиздән барыбызны якынлаштырган уртак мәүзугъларның шактый булуы ачыклана.

Рус зыялыларының «литературные посиделки», «телешевские пятницы», XX йөз башында «Шәрык клубы»ндагы очрашуларны (Тукай халык әдәбияты турындагы нәзаригамәли чыгышын шунда ясаган) хәтерләтеп тора иде безнең күрешүләр, рәсми статуска дәгъва итмәсә дә. Көнлектә, редколлегия утырышында алынган киеренкелектән котылгач, хәмер һәм ашау турында онытып, дивар буена тезелгән урындыкларга ук күчеп утырып, иҗади бәхәсләргә кереп китә торган идек.

Иҗат кешесенең кәеф сихәтләре каләм җимешенең, матбугатта басылып чыгып, җәмәгатьчелекнең бәясенә, ничек кабул ителүенә, дөрес аңлауларына бәйле. Мин аларның әсәрләрен тәнкыйть күтәреп алган чорда, күтәренке күңелле чакларында күрдем. Сирәк булса да, шатлыклары кителгән чаклары да булгалады. Үзләре арабызда яшәгән чорда прозабызның горурлыгы саналган язучыларыбызның әсәрләре дә гел «ура»га кабул ителмәде. Һәр чорда үзгәрә торган, татарча тәгаен тәрҗемәсе табылмаган «конъюктура» аларны да читләтеп үтмәде.

Демократия җилләре исеп, фикер ирегe чоры килгәч, Г. Ахунов иҗаты тирәсендә бәхәсләр дә булып алды. Әдәбият дөньясында бу – табигый хәл. Сүз сәнгате фикер төрлелегеннән башка яши дә, үсә дә алмый. Язучылар оешмасы коридорында, төрле редакцияләрдә, үзара аралашуларда мондыйрак сораулар ишетелгәләде. «Кара алтын табучылар турында, аларның хезмәтен романтик бөеклеккә күтәреп, болай ук илһамланып «Хәзинә», «Хуҗалар» кебек романнарны язу кирәк булдымы икән? «Идел кызы» романы исемен аклыймы? Аның каһарманы мондый яңгыравык атамага лаекмы?»

Төрле суларны айкаган, көфер фикерләрне чайкаган дулкыннар ярларына кайтып, аек акыл өстенлек ала башлагач, мондый сорауларны бирүчеләр азайды. Гариф Ахуновның тирән уйлар, җитлеккән тойгы-кичерешләр белән иҗат ителгән әсәрләренең алга карап, замана сулышын тоеп язылган икәнлеге, вакыт чигенгән саен, тулырак ачыла бара.

Һәр әдәби әсәрнең үз вакыты, үз сәгате була. Әйтик, бүген Мирсәет Ардуанов турында да, нефть чыгаручылар хакында да Ахунов әсәрләрендәгечә язып булмый. Хәзергәчә яшәсә, әлеге хәлләр, вакыйгалар, батырлыклар турында Гариф абый да башкачарак бәян итәр иде. Ләкин сәнгатьчә югарылыкта иҗат ителгән әсәр, үзәккә алынган вакыйгаларга караш, мөнәсәбәт, кыйбла үзгәрү белән, үзенең кыйммәтен югалтмый. Һәр чор әдәби әсәрне үз сәнгатьчә әзерлегеннән, иҗтимагый ихтыяҗыннан, сәяси тоемыннан чыгып бәяләргә тиеш. Әдәбиятның үзенчәлеге дә шуннан гыйбарәт. Татарстан нефте гөрләп аккан чорда олы каһарманнар, фидакяр шәхесләр туа; тетрәнүләр, шатлыклар, фаҗигаләр, бәхетләр – һәммәсе аяк астында. Күпмедер вакыт узганнан соң, ул чорда яшәгән кешеләрнең батырлыгы урынсыз тоелыр, үзләрен аямыйча эшкә бирелүләре елмаю уятыр, булсын дип үрсәләнүләре көлке тудырыр. Ләкин укучы үзен шул чорга куя белергә тиеш. Әйтик, Г. Ибраһимов белән Г. Исхакыйның гасыр башында язылган әсәрләрендә, хәзерге яшәешебез белән чагыштырганда, сәерлекләр азмыни? Зыя хәзрәтнең мунчада скрипка уйнаулары, ирнең өч хатын берлә интегүләре сәер, гаҗәеп түгелмени? Мәсьәләгә икенче яктан килик. Берзаман кара алтын катламнары суырылып бетәр, табигатьнең кояш җылысы, ай нуры, битум кебек байлыкларын эшкә җиккән адәм балалары Татарстан нефте, шул чорда яшәгән ихласлы һәм дуамал кешеләр турында мәгълүматны шул китаплардан гына алыр. Татарстан нефте, башка мөстәкыйль илләрдәге кебек, төп халыкка әллә ни бәхет алып килмәде, тирә-юньне пычратты, табигатьне начар якка үзгәртте, дип әйтүчеләр табылыр. Бу сүзләрдә хаклык барын таныган хәлдә, шуны искәртәсе килә: юллар төзелде, яңа калалар күтәрелде һәм кемнәрдер (шул эш белән шөгыльләнүчеләр) нефть акчаларының рәхәтен бик яхшы татыды, нишлисең, Ходай Тәгалә адәм балаларын тигез яратмаган шул. Ә «Хәзинә», «Хуҗалар» һәм «Идел кызы» романнары – әдәбият тарихында калачак әсәрләр. Соңгы романның төп каһарманнарыннан берсе шактый үзенчәлекле, кабатланмас шәхес булып чыкты. Сүз Габбас мулла хакында бара.

Ясалма күннән эшләнгән кара кепкасын бастырып кигән Гариф абыйның җыйнак гәүдәсе офыкта күренүгә, язучылар йорты тирәсендәге берсе, сүзне башкалар авызыннан тартып алып, хәбәр бирә:

– Җәмәгать, шауламагыз, Габбас мулла килә.

Шул кушамат Ахуновка чәер кебек ябышты. Чөнки Габбас мулла «Идел кызы»ның бер герое гына булмыйча, Гариф Ахунов прозасының ачышларыннан берсе иде. Язучы еш кына әдәбият тарихына бер әсәре, бер образы белән кереп кала. Гариф абый каләменнән төшкән башка характерларны да кимсетмәстән, Габбас мулла образының үзенчәлекле, кабатланмас кеше булуын искәртәсе килә. Ул үз сыйныфы кысаларына, кабул ителгән, күнегелгән күзаллауларга, кагыйдәләргә сыешып бетмәгән хәзрәт булып чыкты. Татар әдәбиятында, бигрәк тә динсез совет чорында, руханиларны артта калган, томана, үз мәнфәгатьләреннән башканы белмәгән, еш кына женси азгын комик затлар, шымчылар итеп сурәтләү модага кергән иде. Без шул гадәткә, дөресрәге гадәтсезлеккә, күнеккән идек инде. Дин әһеле милләтне артка сөйрәүче, мәдәниятне санга сукмаучы, ач күзле булырга тиеш. Аның бар кайгысы – корсак тутыру. Гариф абый каләме тудырган Габбас мулла бөтенләй башка калыпта сугылган. Ул, дин хезмәтчеләренә мөнәсәбәтне үзгәртеп, офыгыбызны киңәйтеп җибәрде. Габбас хәзрәт дөньяга карашы, үзен тотуы, хакимият даирәләренә мөнәсәбәте белән әзер кысаларга сыймый, еш кына үз сыйныфында кабул ителгән кагыйдә-тәртипләрне боза, чыгымчы ат кебек, тәртәне ватып-җимереп чыга. Аңа җәмгыятьнең катгый кануннары тар: яңа хакимият шартларына җайлаша алмыйча бәргәләнә, өзгәләнә. Ул, баш иеп, мескен кеше булып, һәрнәрсә белән килешеп яшәргә теләми, аның гыйсъян йөрәге, тынгысыз җаны ирек, мөстәкыйльлек таләп итә. Әлбәттә инде, кешене почмакка куып керткән, тулы буйсынуны таләп иткән совет җәмгыяте, шул исәптән якын кешеләре андый бунтарь, үзсүзле, үзфикерле кешене кабул итмиләр, аны рәнҗетәләр, җәберлиләр. Җәмгыять белән башимәс, гыйсъян шәхес арасындагы конфликтның кем файдасына хәл ителәчәге мәгълүм иде. Шәхес ватыла, сытыла, имгәтелә, юкка чыгары-

ла. Башка мохиттән булса да, совет җәмгыяте өчен җайсыз кешене Б. Пастернак доктор Живаго образында тудырды, шул әсәре өчен, акчасын алып, рәхәтен күрмәсә дә, әдәбият өлкәсендәге Нобель исемендәге халыкара бүләккә лаек булды («Доктор Живаго»).

Габбас мулла образына Г. Ахунов җир йөзендәге тәртип, шәхес иреге, уйлы кеше белән өстән көчләп тагылган кануннар, кыскасы, җәмгыять белән аның бер әгъзасы арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр турындагы фәлсәфәсен салган, дигән тойгы-хис кала. Шигърияткә гашыйк, үзе дә иҗатка хирыс Живаго образында тәнкыйтьчеләр Борис Пастернакның үзе белән уртак чалымнар тапсалар, ни өчен Габбас мулла образына Гариф абый күңеле тирәнлегендә йөрткән кайбер «көфер» фикерләрен салмаска тиеш иде. Бәлки, Гариф ага үзе дә, Габбас мулла кыйбласында торып, аның белән килешеп, хәтта үзенең җәмгыятькә мөнәсәбәтен, сәясәтне бәяләвен каһарманына йөкләгәндер, үз уй-хисләрен аның авызына, язмышына салгандыр. Әдәбият дөньясы андый хәлләрне күпләп белә.

«Ерак сәфәр»ләрдән кайтып, гаилә корып, дөнья барышын үзгәрәк бәяләү сәләте ачылган А. Гыйләҗев социалистик реализм методы кысаларына сыймаган (икенче яктан, яңа методны «шыпырт» кына таркату эшенә Ә. Еники керешә – «Саз чәчәге», 1955; «Рәшә», 1962), дөресрәге, тәнкыйди реализмны яңа эчтәлек, мәгънә, сурәтләү алымнары белән баеткан «Өч аршын җир» (1962) повестен иҗат итә.

А. Гыйләҗевне колхозлашу елларын караңгы төсләрдә, димәк ки, совет чынбарлыгын бозып, берьяклы сурәтләүдә, адәм баласы фани дөньяда нинди генә байлыкка, дәрәҗәгә ия булмасын аңа, ахыр чиктә, өч аршын җир җитә, дигән фикердә үлем фәлсәфәсен, фатальлекне алга сөрүдә гаепліләр (К. Фасеев).

Тәнкыйтьнең ачысын-төчесен шактый татып, үзен дөрес аңламаулары өчен гарьләнгән А. Гыйләҗев, кабихларның күзенә чалынмау хәерлерәк булыр, дип, арткы рәтнең почмагында посыбрак утыруны мәгъкульрәк күрә, үз сәгате суккынны көтебрәк яши, яңа әсәрләр иҗат итә, балалар үстерә.

Борынгылар, дөнья куласа, бер әйләнә бер баса, дип, юкка гына әйтмәгәннәрдер. Үткән гасырның соңгы чирегендә демократия җилләре исеп, мәңгелек саналган кыйммәтләр бәяләрен югалтып, дөньяга, шул исәптән әдәбият үсешенә, үзгәрәк күзлектән карау вакыты суга. Совет чорын, җитәкчеләрен мактауга багышланган, йөзек кашы кебек кадерләп йөртелгән әсәрләр әйләнеп торган көпчәктән төшеп калган тиен хәлендә калалар. Каһәрләнгән, типкәләп йөртелгән иҗат җимешләре, киресенчә, яңа, күп очракта дөресрәк бәяләрен алалар. Аерым алганда, кеше мәңгелеккә кереп ятырга тиешле өч аршын җирне олылаган дип, берьяклы бәяләнә килгән «Өч аршын җир» XX гасыр татар прозасының казанышы, әдәбиятның яңа үсеш юлларын барлаган энҗесе дип табылды. Үз хакыйкатенә инанган, дөреслекнең ахыр җиңәсенә ышанган А. Гыйләҗев, үзен соңарган ләббәйкәләргә, мактауларга исе китмәгәндәй тотса да, алдагы рәткәрәк күчеп утырды, озак еллар дәвамында язучылар берлегенә кабул итү комиссиясенең рәисе вазифасын башкарды.

«Өч баһадир» минем күңелемдә бер мизгелгә дә онытылмас затлар, иҗат олимпының түренә күтәрелгән каләм осталары, тормыш ияләре булып яшәүләрен дәвам итәләр. Дөнья барышының даими алышынып, үзгәреп торган матавыкларына, сөенечне куа килгән көенечләренә баш бирмичә, үз шәхси тормышларын, иҗатларын татар халкы язмышы белән үреп бирү сәләтенә ия шәхесләр, барына мәэмүн-канәгать булып, ясалма мөнәсәбәтне араларына кертмичә, яшәү үрнәге калдырып киттеләр.

Өчесе дә, бары бер тәнкыйтьчене генә танып, аны гадел һәм әдәби әсәрнең эчтәлеген сөйләүгә караганда, эчке яңгырашын, теленең матурлыгын бәяли белә, дип санадылар. Ул – шул чорның бердәнбер (ул заманда нигездә рус телендә язган Р. Мостафинны санамаганда) профессиональ тәнкыйтьчесе, югары зәвыклы, мәкаләләрен әдәби әсәр дәрәҗәсенә күтәрә алган Фәрваз Миңнуллин иде.

Мактау сүзен, азау тешен суырып, авызын кыйшайтып, дегетен тамызып кына чыгарса да, аны хөрмәт итәләр, фикеренә колак салалар, табигать баласы, ихласи җан Фәрвазга ни әйтсә дә, ничек бәяләсә дә килешә, «бу әсәрең йомшак,

каһарманының үзенә хас билгесе табылмаган» дип ычкындырганда да, аңа үпкә белдереп, табын яныннан торып китүче булмады. Фикерен үзләренә өздереп әйтсә дә, вак-төякне матбугатка чыгармады.

Мәһдиевнең колхоз тормышына багышланган «Мәңгелек яз» романының әле генә машинкадан чыккан вариантын Фәрваз үзе дә җентекләп укыды, бәяләмә өчен (Татарстан китап нәшриятында эшли иде) миңа да бирде. Якын дустыбыз булса да, Мөхәммәткә романның буш сурәтләүләр, диалоглар исәбенә озынгарак китүен, колхоз рәисен артык бизәп күрсәтүен, юк конфликтны бар итеп, аны ясалма тизлек белән чишүен искәрттек, башка сюжет чатаклыкларына игътибар иттек. Ният-максатыбыз изге иде: Мәһдиев кыска җөмләдә төгәлләнгән фикер әйтә алган, дөньяны ироник бәяли белгән югары кимәлле сүз остасы итеп танытган әсәрләре үрендә калырга тиеш. Фәрвазның телдән әйткән фикерен тыңлап, минем язмамны (ул чорда нәшрият бәяләмәләр өчен түли иде) карап чыккач, авторыбыз аркасын туры тотып, озынча тар бүлмәнең ишеге белән түре арасында йөреп алгач, горурлыгын җиңеп (без кем дә, ул кемсә), тәнкыйтьне өлешчә кабул итеп, чынында әсәрен шактый кыскартып, үзгәртеп бастырды. Колхоз рәисләренә мөкиббән китеп, җирнең кендеге итеп сурәтләгән кайбер прозаикларыбыз әсәрләре белән чагыштырганда, «шедевр» булса да, минемчә, «Мәңгелек яз» – Мәһдиев мирасының иң йомшак әсәре.

Язучылык шөһрәтенең югары үренә күтәрелә килгән Мәһдиев безнең белән килешкәндәй булса да, матбугатта романын яклап, үзенең дөреслеген исбатлап чыгарга булды: «Актаныш районы, «Чишмә» колхозы рәисе Ясәви агай «сөйләгәннәрнең йөздән берен генә файдаланып, мин «Мәңгелек яз» дигән роман яздым. Нигәдер, әдәбиятчылар (ул Ф. Миңнуллин белән Т. Галиуллинны күздә тота дип уйлыйм. Ул – тәрбияле кеше, ачыктан-ачык әйтми.– *Т.Г.*) минем бу әсәремне кабул итмәделәр. Кайберәүләр, «Мәһдиев колхоз тормышын белми, төп героеның гаилә, шәхси дөньясында гына казына» дип язып та чыктылар (Г. Ахунов, мәсәлән, мәшһүр колхоз рәисе Фәйзи Галиев фикерен китереп, «Казан утлары»нда шулай язды)».

Язучының иҗат җимеше үзенә баласы кебек якын була. М. Мәһдиев тә әсәрен аклау юлын сайлый: «Болар хаклы, әйе, мин бүгенге агротехниканы, ветеринария, селекцияне, механизацияне белмим, комбайннарның маркасын аермыйм. Ләкин бит врачлар турында роман язучылар да медицинаны белмиләр. Әдәбият бит – *кеше турындагы фән* (курсив аныкы.– *Т.Г.*)».

Автор бу очракта аңлы рәвештә укучыны читкә алып китә. Берәү дә аңардан югарыда санаган фәннәрне белүне таләп итми. Сүз конфликтның ясалма булуы, социалистик реализм схемасы буенча бик тиз хәл ителүе, колхоз тормышын, бигрәк тә рәисен бизәп сурәтләү һәм акланмаган озынлык турында бара. Ниһаять, алдынгы кеше турында заказ белән язылган берәр әсәрнең уңышлы чыкканын хәтерләмим. Гомерләре прототип гомереннән озын булмый. Мәһдиев әсәре генә гомуми чыгармадан искәрмә була алмый.

Мәһдиевнең «классик сюжет» кора белмәвенә, дөресрәге, кирәк санамавына күпләр игътибар итә. Ф. Яруллин истәлекләренә болай дип теркәп куйган (1984, 7 июль): «Казан утлары»ның 6 нчы санын укып чыктым. М. Мәһдиевнең «Мәңгелек яз» романы ике санда килде. Искитәрлек түгел. Теле шәп. Ләкин әсәрләрен бер сюжетка кора белми. Ахырыннан укысаң да барыбер. Сюжетсыз, конфликтсыз әсәр – әсәр түгел инде ул. Автор, әйтерсең, укучы алдында бер зур агачны тотып юна башлый. Ахырга таба ул агачтан йомычкадан башка берни дә калмый. Әсәр башындагы геройларны онытып, башка персонажларга күчә. Теленең җорлыгы, халыкчанлыгы укучыны тотып тора. Бәлки, сюжетсыз әсәрләр дә кирәктер. Халык укый бит... Бу – жанрны төрләндерүнең бер ысулыдыр, бәлки. («Казан утлары».– 2011.– № 9.–169 б.) Мәһдиевне «сюжетсызлыкта» гаепләп, тәҗрибәле язучы соңгы җөмләсе белән «Мәңгелек яз» авторын да, гомумән, соңгы елларда вакыйгага җебенә ябышып ятудан бигрәк, кешенең психологик халәтен, рухи эзләнүләрен сурәтләүгә, мохит белән катлаулы бәйләнешләренә, аң төпкелендә яткан бәргәләнү-сызлануларга өстенлек биргән прозада барган «төрләндерүгә» омтылышны аклый да куя. Фәнни яктан бәяләгәндә, «Торналар төшкән җирдә», «Бәхилләшү» кебек

иҗат җимешләре белән чагыштырганда, «Мәңгелек яз» – Мәһдиевнең «сюжетлы», үзәк каһарманлы романы. Классик кануннарга җавап биргән әсәрләрне «таркаулыкта» гаепләү очраклары да бар бит әле. Мәктәп дәреслекләренә кергән язучыларны пәйгамбәр дәрәҗәсенә күтәреп йөри, әсәрләренә тел-теш тидерүне, тәнкыйтьне күз алдына да китерә алмый, булса, аны изге кое суын пычраткандай кабул итә идек китап сүзенә ышанып яшәгән чорда. «Хождение по мукам», «Пётр I» кебек төгәл эпик вакыйгалы, анык сюжетлы романнар авторы Алексей Толстой бер мәкаләсендә «Анна Каренина» романының төзелешенә каты бәрелә. Янәсе, Л. Толстой әсәренең бүлекчәләрен, карта бутаган шикелле, урыннарын алыштырып укысаң да, берни югалтмыйсың, мәгънәсе дә, яңгырашы да шул ук кала. Әдәби кануннарга тәгаен җавап бирү яссылыгыннан гына килеп бәяләгәндә, А. Толстой, әлбәттә, хаклы.

Шул ук вакытта Лев Толстойның бөеклеге әсәрен тормышның үзе шикелле каршылыклы катлаулылыгында, сикәлтәле итеп сурәтли, төп игътибарын җан диалектикасын ачу алымнарын төрләндерүгә юнәлтүендә түгелме соң? Мәһдиевнең, чәчәктән чәчәккә сикергән бал корты кебек, бер вакыйганы бәян итүне төгәлләмичә, икенчесенә күчүе, бер каһарманының «эшен бетермичә», икенчесе белән мавыгып китүе – аның ачышы, заман таләбе түгелме? Дөньяны бу рәвешле сурәтләүнең дә яшәргә тиешлеген, «иҗат иреге» дигән төшенчәгә җавап бирүен Мәһдиев иҗатына, өслүбенә мөкиббән китеп яшәгән шактый укымышлы, төрле һөнәр укучылар фикере дә раслый. Байтак кешедән (мәсәлән, «Корстон» ял итү, күңел ачу үзәге генераль директоры Рәис Мөбәрәкҗанов, элеккеге мәгариф министры урынбасары Гаденан Садриев һ.б.) мондыйрак сүзне ишеткәнем бар: эч пошканда, үзеңне кая куярга белмичә бәргәләнгәндә, Мәһдиев томын кулыңа алып, теләсә кайсы битен күз йомып ачып, берничә җөмләсен укуга, бик эссе көнне салкын су белән коенгандай, иркенәеп, сихәтләнеп, «яңа дөньяда» яшәп алгандай уңайланып китәсең.

Димәк, бу мизгелдә адәм баласына сюжетың да, төгәлләнгән вакыйгаң да кирәк түгел. Аны Мәһдиевнең сүзе,

җөмләсе, шулар аша күңелен әсир иткән моңы, сагышы, фәлсәфәсе, табигатькә мәҗүсиләрчә табынуы, тормышны бизәмичә, иннек-кершән якмыйча сурәтләве, нечкә күзәтүе – «йомычкасы», милләтнең бәхетле киләчәгенә ышануы әсир итә. Бу инде югары поэзия дигән сүз. Шигырьнең шул чордагы хисси халәтеңә туры килгәнен генә табып укыйсың ич. Кайсы вакыт сайлап, эзләнеп тормыйча...

Мәһдиев феноменын ачу, әдәбият һәм кешелек кануннары буенча шәрехләү – киләчәк эше дип саныйм. Аның иҗатына иң гадел бәяне вакыт галиҗанәпләре бирер. Кеше – цивилизация тоткыны – табигатьтән, табигый яшәештән ераклашкан саен, күңел тыпырчынуын бастыру «даруын» Мәһдиев һәм башка элгәрләребезнең әсәрләреннән эзләр, дип уйлыйм. Мондый фаразга нигез җитәрлек. Читкәрәк китүем өчен укучыдан гафу үтенеп, янәдән Ф. Миңнуллинга әйләнеп кайтыйк.

Якташы Ф. Миңнуллинны, әсәрләренә тәнкыйть сүзе белән кагылса да, ни кыйланса да кыйлансын, тик еламасын гына дигәндәй, Мәһдиев гафу итә. Фәрваз үзенә булган җылы мөнәсәбәттән, биләгән урыннарыннан кирәгеннән арттырыбрак та файдалана иде бугай вакыты белән.

Гадәттә тәнкыйтьче төрттереп, җанга тиярлек сүз әйтүгә әзерләнгәнен авыз, бит торышын үзгәртүдән, ягъни, хәрбиләрчә әйтсәк, «арт» әзерлектән башлый. Әүвәл салпы якка салам кыстырган була да, шунда ук ачысын тамызып куя.

– Мәһди, син – бөек язучы, хәзерге татар прозасының мактанычы... Тик син кеше буларак «незрелый».

Мөхәммәт, беренче җөмләне ишетүгә «кабынган» елмаюын сүндерә алмыйча, авызын ерып утыра бирә. Шулай да бу гаепләмәне җавапсыз калдырсаң, тәнкыйтьче аякларын салындырып муенына менеп атланырга мөмкин. Дус дигәч тә...

– Дәлилләрең кая? Бу бит – теләсә кемгә әйтелерлек коры гаепләү.

Фәрваз, юан бармагын бөкләп, «дәлилен» китерә.

– Мәсәлән, син саранлык чүтеннән Әмирхан Еникидән генә калышасың. Хәтта Туфан Миңнуллин да синнән соң килә (әле генә Язучылар берлеге рәисе итеп сайланган драматургка үпкәләп йөргән вакыты иде).

Мөхәммәтнең теле усал, күзәтүчәнлеге хәтәр, бәясе куырып алырлык булса да, Фәрвазга нисбәтән мәрхәмәтле, риясыз, гафу итүчән, дидек.

Яшьлегендә, бигрәк тә аспирант елларында акчага кытлык кичергән Мәһдиев саранлык-юмартлык турында сөйләшүләрне авыр, үртәлеп кабул итә, ә бу — мәүзугъ якташының яраткан «хоббие»: форсат чыккан саен, язучыларны шул яссылыктан төркемнәргә бүлә башлый. Мөхәммәтнең кысмырлыкта гаепләгәнне өнәмәгәнен дә яхшы белә. Авырткан тешне кармалап торган тел кебек, Фәрваз гел шул якка каера. Мөхәммәт бу шаяртуны чынга ала. Юморист үзенә кагылмаган көлкене генә аңлый шул.

— Фәрваз ахири, син хаклы түгел. Янымда акчам булганда, мин дуслар өчен кызганып, саранланып тормыйм.

— Син бу сүзеңнең хаклыгын хәзер үк исбат итә аласың,— ди Фәрваз, уенны дәвам итеп.

Сез инде, Мәһдиев югалып, ыкы-мыкы килеп калгандыр, дип уйласагыз, бик нык ялгышасыз. Юк шул, сез Мөхәммәтнең холкын «ничурта да» белмисез икән. Аркасын уклау йоткандай туры тотып, мәгърур атлап, прозаигыбыз кибеткә чыгып та китте, ун-унбиш минуттан коньяк күтәреп, лимон тотып кайтып та керде. Фәрваз, шешәне кулына алып, селкетеп, тышындагы язуны укып, азау тешен суырып алды.

— Классик вә доцент башың белән өч йолдызлы коньяк күтәреп кайткансың. Биш, һич югында дүрт йолдызлыны аласы идең. Акчаң җитмәгәндер,— дип мырлый-мырлый, миңа күз кысып, стаканга үрелде.

Мөхәммәт Мәһдиев прозасының яңачалыгын, илаһи матурлыгын, халкыбызның моң-зарын, хатын-кыз психологиясен иң белеп сурәтләгән, ямьле, тәмле, җиләкле, мамыклы тел иясе булуын ачып биргән тәнкыйтьче-галим нәкъ менә Фәрваз Миңнуллин булды.

«...Без Мөхәммәт Мәһдиев белән байтак еллар дуслар булып яшәдек. Танышлар уртак иде, серләр уртак иде. Миңа аның бөтен тормыш юлы, туганнары, нәсел-нәсәбе таныш»,— дигән юллар («Яшьлекне сагыну» мәкаләсеннән) Фәрвазның алдарак китерелгән шаяртуларын аклый да куя.

Мөхәммәт тә «бурычны» өстендә калдыра торган шәхес түгел иде.

Саранлык-юмартлык «уеныннан» берничә ай үткәч, Фәрваз грипп авыруы белән чирләп, хастаханәгә эләкте. Мөхәммәт белән хаста янына киттек, бүлеген дә, бүлмәсен дә белмибез.

Кечкенә тәрәзәгә шакып, аннан ак халатлы, зур кара күзле кыз күренүгә, Мөхәммәт телгә килде:

– Карале, сеңелем, сезнең бульнистә тозлы кәбестә суы кебек аксыл чырайлы, рәсемдә ифрат матур чыга торган бер абзый ятарга тиеш. Палатасын белмибез.

– Фәрваз Миңнуллин абыйдыр. Ул 18 нче бүлмәдә, өченче катта. Тик анда кертмибез. Карантин.

Мәһдиев теге вакыттагы коньяк алдырып үртәүнең үчен, минем алда гына булса да, чыгарды тәки, дип уйлап куйдым.

Фәрваз үзе безнең янга төште. Якташлар аркаларына суккалый-төрткәли күрештеләр, бер-берсенә теләкләрен әйтештеләр. Сүз күбрәк әдәбият, нәшриятта (ул чорда тәнкыйтьчебез аның баш редакторы иде) басыла алмыйча яткан кулъязмалар турында барды. Икесе дә чын дуслыкның кадерен беләләр дип, мин читтәнрәк күзәтеп утырдым.

Фәрвазның төртмәле теле Г. Ахунов белән А. Гыйләҗев әсәрләрен дә «чагып» алгалады. Корт тешләгән шикелле, көтмәгәндә, уйламаганда. Беренчесен яшәешнең гел якты, матур якларын гына сурәтләүдә гаепләсә (бигрәк тә документаль нигезле әсәрләрен күздә тотып), А. Гыйләҗевне иң мактаулы әсәрләренең берсе – «Җомга көн, кич белән...» повестенең каһарманы, яшьлегендә ут уйнаткан Бибинурны, карт көнендә, артык мескен, салынып төшкән, бөтен барлыгын, саулыгын биреп үстергән балалардан күктән иңгәндәй мәрхәмәт көтеп ятуы, гафу итүе дөреслеккә туры килми, дип тәнкыйтьләде.

Аяз абый да үз ышанычыннан тиз генә кайта торган зат түгел иде.

– Бибинур образында мин татар хатыннарына хас олы җанлылыкны, динебез өйрәткәнчә, йомшаклыкларны кичерә белүне, авырлыкларга тешен сындырып булса да түзә

алуны, хәтта корбанчылыкны күрсәтергә теләдем. Син, парин, бу язмышка берьяклырак киләсең!

Фәрвазында үҗәтлек ун кешегә җитәрлек. Урыныннан сикереп торып, үз бәясен якларга керешә.

– Бу образың барыбер ясалма. Кешенең изгелеге җир суалчаны кебек тапталырга, сытылырга тиеш түгел. Үзебез белгән кешеләр арасыннан шундыйрак берәр мисал китерә аласыңмы?

– Бибинур – җыелма образ. Гадәти бәяләрдән өстен торган, идеаллаштырылган шәхес. Грамоталы тәнкыйтьче булarak, син әдәби әсәрнең тормышны нәкъ булганча сурәтләве мәҗбүри түгел, язучының хыял җимеше турында да хәтерлисеңдер, дип уйлыйм.

Дөреслек өчен шуны да искәртергә кирәк: хәзерге тәнкыйтьтә әдәби әсәрләр халкыбызны көрәшкә дәртләндереп, үз хокукларын яклый белүгә чакырып торырга тиеш, ә Бибинур язмышка буйсынып яшәүгә, мескенлеккә генә өйрәтә, дигән фикерләр дә әйтелә (мәсәлән, Яр Чаллы тәнкыйтьчесе Гомәр Даутов).

Хәзер дә, сирәгрәк булса да, без Равил Файзуллин белән очрашып, аралашып, традицияләрне сакларга тырышып яшибез. Баш мөхәррирнең җәелеп аркасын кашырга да вакыты юк шул. Үз иҗатын, журналның тиражын кайгыртасы, пырдымсыз авторларны тынычландырасы, түрәләр белән мөнәсәбәтне билгеле бер дәрәҗәдә тотасы һәм башка бик күп хәсрәтләре бар. Шул ук реклама кәгазьләре җәелгән ялтыравык өстәл янына утырып, хәл-әхвәлләрне, гаилә тәртипләрен белешкәннән соң, «алтын чорыбызны» – Мәһдиевнең шук телен, урынлы кыстырган төрттерүен, Аяз абыйның ачы миләш кебек витаминлы сүзен, «парин»ын, Ахуновның «мин башкачарак уйлыйм» дип сикереп торуын искә төшерәбез. Күрәсең, үткәннәрне сагыну, элгәрләрне күтәрү – буыннарны бәйләп килүче, кешелекнең асылын билгеләүче җанлы җептер, хәтерне яңартып торучы иң камил, иң мөкаддәс хистер. С. Хәким Муса Җәлилләрне юксынып яшәве турында күп язган. Г. Бәширов та үзеннән иртәрәк киткән Х. Туфан, Ф. Хөсни, И. Гази, М. Әмир кебек аркадашларын сагынып картаюы турында истәлекләрендә

бик үтемле әйтеп калдырган. Менә без дә, Габдрахман абый улы белән, бик «булдыклы» гына зарланып алабыз.

– Киңәшеп, туарылып, эчеңне бушатып утырырдай кешеләре дә азая бара. Әхлак нигезләре үзгәргән чорда йөрәк серең белән уртаклашу кебек «сантиментлар» яшәеш тәртәсенә сыймый торгандыр шул.

Ә инде саубуллашканда, «сагыну хисен саклый алсак кына, кешелек сыйфатларын югалтып бетермәс идек, кичерешләр сафлыгы җанның үлчәү бирәмлеге булуын онытмасак иде», дип тә уфтанып куябыз, болары инде берәүгә дә кирәк булмаса да.

«Өч баһадир» һәм бер тәнкыйтьченең инде берсе дә арабызда юк. Бу олы шәхесләрнең гомер йомгакларында шунысы сөенечле: алар үзләреннән соң үлмәс, тутыкмас мирас калдырып, әдәбият күгебездә һәркайсы үз йолдызлыгын кабызып, сәламәт акыл, аек психологик халәт белән исәннәргә хәер-фатиха биреп, озын гомер теләп, мәңгелек хозурына күчтеләр. Алдагы бүлекчәләрдә сүз ошбу шәхесләрнең минем күңелдә калган холык-фигыльләре, менәзләре, кешелек сыйфатлары турында барачак.

Аяз ага!

Кемгә ничектер, миңа «Аяз Мирсәет улы» дигән рәсми мөрәҗәгатькә караганда, «Аяз ага» дип эндәшү, күренекле сүз остасын олылау белән беррәттән, ниндидер рухи якынлыкны, хөрмәтне тулырак чагылдыра, җылырак яңгырый кебек. Холкының кырыслыгын бер мизгелгә дә онытмыйча, кәефе яхшы вакытта, үзенә дә шулай мөрәҗәгать итә, ә инде хатыны Нәкыя янында булганда, «җизни» дип тә ычкындыргалый идем. Соңгысына кечтеки генә хакым да бар иде шикелле. Чөнки мин аның гомерлек турылыклы юлдашы, шулай ук туган халкының язмышы, теле өчен җанатып яшәгән Нәкыя ханым белән Казан дәрелфөнүненең татар теле һәм әдәбияты бүлегендә биш ел бергә сабак алдым. Аяз ага, нахак яла аркасында, яшьлегенең иң матур чорын урлаган сөргендә булып кайтканнан соң, безнең төркемнең чибәр, акыллы, сабыр кызларыннан берсен – Нәкыяне оста мәргән кебек «чиертеп» алды. Группабызда аны иң матуры иде

дип расларга алынмыйм, бердән, һәркемнең үз зәвыгы булса, икенчедән, бу «урынга», әтисе ишек төбен саклаучы гына булса да, «мин – военком кызы» дип, тәтен җибәрүдән ләззәт тапкан Галия белән чем кара йөзле, кара күзле, «кыргый» матурлыкка ия Римма да дәгъва итеп йөрделәр. Чебешләрне көзен саныйлар, дигәндәй, төркем кызларының берсе дә хатын-кыз вазифасын Нәкыя кебек, шундый күркәмлек белән үти алмады, дисәм, зур ялгыш булмастыр.

Нәкыя белән дуслашып, безнең төркемгә кергәләп йөргәндә, Аяз ага күңелгә җитез хәрәкәтле, фикерен берәүдән дә курыкмыйча өздереп әйтә белүче, тәҗрибәле вә хакыйкатькә турылыклы зат булып кереп калган. Ул чорда әле аның тормыш юлын, дөньяның ачысын-төчесен һәрьяклап татыган кеше икәнен бөтен тулылыгында белми идек.

Шәхес культы фаш ителгән булса да, аның коточкыч начар яклары турында тулы тавышка, ачыктан-ачык сөйләшү сәгате сукмаган иде әле.

Төркемебезнең тулы ай кебек түгәрәк битле, чем кара озын чәчле, сабыр холыклы, укуга һәвәс кызы Нәкыя белән Аяз абый электән таныш булып, хат алышып торганнар икән. «Тегеннән» кайткач, группабызның булачак кияве, күпмедер вакыт көндезге бүлектә «бала-чага» белән буталып йөрде дә, читтән торып уку бүлегенә күчеп, «Чаян» журналында эшли башлады. Аның инде гаилә корып, балалар үстереп яшәү вакыты җиткән иде. Социологлар фикеренчә, утызның өске ягына чыккан ир-ат, буйдак тормышның «тәмен» татыгач, үзенә тиң ярын табу, гаилә мәшәкатьләрен җилкәсенә салу мәсьәләләрендә шикләнә, икеләнә, аны җаваплылык, шәхси иреген югалту куркыта башлый. Аяз абый тимерне кызуында суга торган егет булып чыкты. Нәкыя дә «өлешемә тигән көмешем» дип, артык кыстатып тормыйча, кыз-кыркын тормышы белән хушлашырга булды. Көндезге бүлектә укуын ташламыйча, дипломын безнең белән бергә алып, Аяз абыйның текә холкына җайлашып, кирәк чакта салпы ягына салам кыстырып, шул ук вакытта тормыш-көнитеш дилбегәсен кулыннан ычкындырмыйча, минем белүемчә, үрнәк гаилә корып, төп көчен улларын тәрбияләүгә бирде.

Килен кешенең тәкъдиме беләндер, дип уйлыйм, безнең төркемнән Аяз абый туйларына өч егетне чакырды: соңыннан радио дикторы, шунда ук әдәби-музыкаль тапшыруларның баш мөхәррире, Оренбург егете Рим Кәримов, группаның комсоргы, «Татарстан» журналының редактор урынбасары Шәүкәт Сәйфетдинов һәм ошбу юлларны язучы шундый бәхеткә тарган затлар булдык. Мәҗлес Островский урамында, «Татарстан» кунакханәсе янында диярлек урнашкан йортта, кайсыныңдыр ерак туганнарының фатирында узды (ул йортларны инде күптәннән «җир йотты»). Ике якның да туганнары, Аяз абыйның үзе көндез укып алган төркем егетләре, кызлары чакырулы иде. Шул чор өчен өстәл шактый әгъләдән әзерләнгән булып чыкты: графиннарга, шешәләргә салып куелган «шайтан суы», җемелдәп «күз кысып», әллә нинди сөенечле вәгъдәләр биреп, ялт-йолт итеп үзенә чакырып тора. Без – томшыклары ныгып кына килә башлаган чебешләр – беренче курс талиблары мондый кичәләрдә үзеңне ничек тотарга икәнен белмибез, шуңа күрә, салганны эчеп, алда торганны ашап, кушканны үтәп, тәмам сәлперәеп төшкәнебезне сизми дә калганбыз. «Җемелдәп» утырган савытлардагы эчемлек, тәмле булып, җиңел эчелсә дә, аякларны, билләрне мамык белән тутырылган хәлгә китерүгә «сәләтле» булып чыкты. Аяз җизнинең сыйныфташлары, күбесе соңыннан күренекле язучылар, журналистлар, фирка хезмәткәрләре – Хәмзә Зарипов, Мөкатдәс Юсупов, Минвәгыйз Зәйнетдинов, Фаяз Хисмәтуллин (Дунай), Мидхәт Миншин, Фәрваз Миңнуллин, Кояш Тимбикова кебек, шул чорда ук үзләре турында югары фикердә торган гаярь егетләр-кызлар иде. Теге серле эчемлек аларның кулларын, телләрен «чишеп» җибәрде. Беришесе ата-анасының дәрәҗәсенә сылтама ясаса, икенчесе шагыйрьлеге, вакытлы матбугатта басылуы белән мактана, төрлечә туарыла, шаулаша башладылар, сөйләүчене бүлдерү ешайды. Туйның фәлән еллардагы барысы бергә сөйләгән колхоз җыелышына әверелү куркынычы туды. Мәҗлеснең ямен җибәрүчеләр күбәюгә, кияү, дилбегәне кулына алып, үзенең холкын күрсәтә, тәртип бозучыларны, мактанчыкларны чоланга алып чыгып, әрдәнә итеп өеп куя, беришесенең «ипи шүрлегенә»

дә менеп төшә башлады. Аның җитез гәүдәсе, елгыр йодрыгы әле бер почмактагы кабыргада, әле икенче яктагы арт сандa ялтырап-ялтырап күренеп алды. Берничә дәкыйка эчендә ул өйдә дә, чоланда да тәртип урнаштырды. Ярдәмчеләре дә бар иде бугай.

Үзе туктаусыз бер үк җөмләне кабатлый.

– Фукалар (соңыннан без аның «с» хәрефен безгә фарсыдан кергән «ф» белән алыштыруына төшендек), мин сезне якын итеп, җан дуслар күреп, шатлыгымны уртаклашырга чакырдым. Ә сез җәнҗал, тавыш чыгарып ятасыз. Бөек буласыгыз килсә, төрмә тоткасын имеп кайтыгыз, фукалар!

Баш хәрефе алышынган сүзне кат-кат әйтсә дә, Аяз җизнинең йөзендә җиңүче кыяфәте юк. Чырай чытыклыгына караганда, аның бу «эшне» мәҗбүри башкаруы сизелә иде. Ул бары тик туйның тыныч, тәртипле узуын теләде кебек. Ә беренче сыйныф балаларының, ягъни безнең, тавыш чыгарырлык түгел, сөйләшерлек тә дәрманыбыз юк, почмактан тамаша шаһитлары булып утыру өчен генә яраклык идек.

Аяз белән Нәкыянең туйларында булган хәлләр турында матбугатта да беркадәр фикер әйтелде, бигрәк тә мәҗлестә катнашучыларның үзара очрашуларында сүзләр, бәяләр шактый булды. Үзләренә җилдәй җитез йодрык эләккәннәре бу хакта сүз куертуны бер дә төнәмәделәр.

Аяз абыйның чүкеч йодрыгы эләкмәгәннәре, чүпрәне өсти торып, вакыйгалар агышын елдан-ел арттыра, куерта, детальләрне өсти тордылар. Күренекле публицист, шагыйрь Мидхәт Миншин А. Гыйләҗевнең үзен «дөмбәсләвен» искә төшерүне аеруча авыр кабул итә иде.

– Ничек инде без, шундый таза егетләр, кеп-кечкенә Аяздан кыйнатып торыйк, ди. Тузга язмаганны сөйләп йөрмәсәгез,– ди торган иде ул, ачулы күзләрен уйнатып.

Инде янәдән мәҗлескә әйләнеп кайтсак. Без «чебешләр»-нең үз хәле хәл. Аяклар зиһен шәрифләренә буйсынмый, буыннар боламык кебек изелеп төшкән. Ярый әле, шул тирәдә генә, Киров урамының (хәзерге Московская) башында гына, ике катлы агач йортта фатирда тора идек. Шәүкәтнең дә Гадел Кутуй урамына, тулай торакка кайтырлык хуты калмаган иде, безгә иярде. Икенче көнне иң таләпчән укытучыбыз

профессор Диләрә Тумашеваның лекциясенә дә бара алмадык. Ә туйда алган истәлекләр һаман да күңелдә, хәтердә. Мәҗлестә катнашкан, дәрт чүлмәкләре ташып торган егетләр һәркайсы кабатланмас чалымнары, сөйләшү манералары белән һаман күз алдында торалар. Күбесе инде гүр ияләре. Туйда катнашкан ике сабакташым, дусларым Шәүкәт белән Рим да җир астында. Татар мәдәнияте үсешендә һәркайсы үз үрен калдырган бу егетләрне тезеп бастырасы, янә бер кат Аяз абыйдан «тәртипкә» чакыртасы иде дә, үткәннәргә хәтер канатында гына кайтып була шул. Кичә булган хәлләр онытыла барса да, яшьлек хатирәләре күңелдән китми икән.

Шактый вакыт узгач, истәлекләргә бирелеп утырганда, мин тәнкыйтьче, туйның түрендә кияү егетенең дусты булып утырган Фәрваз Миңнуллиннан «ни өчен Аяз абый шулай чыгырдан чыкты, сабакташларын тукмап ташлады икән» дип сорагач, уйланып торгандай булды да:

– Мин Аязны аңладым һәм гафу иттем. Мидхәт Миншиннан башкалары аны-моны әйтмәде, үпкәләмәделәр кебек. «Каядыр бәрелгәнмен бугай. Кабыргалар кара янып чыккан», – дип, зарланучылары булды анысы. Күбесе хәтерләми дә. Мин шешәләрдәге самогонның, чуваш кардәшләрнең аңкаласының көчен бәяләп, су гына эчеп утырдым.

– Аяз абыйның болай кыйланышын ничек аңларга инде?

Һәр нәрсәдә тәртип, тимер мантыйк тарафдары Фәрваз, уң кулының бармакларын берәм-берәм учына яткыра-яткыра, иренмичә санап китте:

– Беренчедән, Нәкыянең мәртәбәле туганнары алдында сабакташларының исерешеп тәртип бозуларын күрсәтәсе килмәде Аязның. Исеңә төшер (шуны аңларлык хәлдә булуыңа шикләнәм, дигән мәгънәдәрәк күзен уйнатып алды): табында утыручылар сизми калсын, дип, ул әүвәл, чоланга чыгу ишеген ябып куйды. Икенчедән, үзе дә бераз салмыш иде. Аяз күңелен тырнаган хисләренә ирек бирде. Өченчедән, һәм иң мөһиме, димәк, сөргендә утырганда, надзирательләр үзенә шул ук сүзне әйтә-әйтә кыйнаганнар. Тирәндә, аң төпкелендә утырган ачу, үпкә хисе кайнаган май шикелле өскә чәчрәп чыккан. Билгесез көчләрдән үч алып, йөрәген тынычландырды. Гарьләнүе, рәнҗүе белән бүлеште.

– Соң бит алар – аның дуслары, сабакташлары,– дип, үҗәтләнүемә дә Фәрвазның исе китмәде. Чыраен сыгып алды да:

– Ул мизгелдә Аяз өчен барыбер иде. Кызып киткән вакытта кеше үзен төрлечә тотарга мөмкин; тик кул астына гына эләкмә. Кыйнаганда, надзиратель дә берсенең дә фамилиясен сорап тормагандыр, дип уйлыйм. Сүгенү сүзләре дә шул чорныкы.

Соңгы җөмләнең мәгънәсен аңлап җиткермәсәм дә, ачыклап торуга җөрьәт итмәдем. Адәм баласының психологик халәтендә ни ятканын, вулканның кайчан тышка бәреп чыгасын фаразлап булмый, күрәсең, дип кенә нәтиҗә ясадым.

Соңыннан Аяз абыйның кемгәдер кул күтәргәнен (шул исәптән хатынына), якасыннан алганын күрмәдем, ишетмәдем, гөнаһысына керә алмыйм. Туры сүзнең тәэсире йодрыктан көчлерәк икәнлекне кем генә белми икән. Сәләте чикле, дәгъвасы хәттин ашкан каләм тибрәтүчеләр арасында Аяз Гыйләҗевнең ачы, нигездә гадел теленә эләккәнче, берне тондырсын гына иде, дип уйлаучылары да аз булмагандыр. Ул абруйлы, мәртәбәле, исемле язучыларның әсәрләренә бәясендә дә дөресен, уйлаганын әйтүдән куркып тормый иде.

«Йәгез, бер дога!» романын язганчы, А. Гыйләҗев лагерь тормышы турында сөйләргә, җанын җәрәхәтләп искә алырга яратмады.

Ибраһим Салахов, Гурий Тавлин, иң соңыннан Аяз Гыйләҗевнең Сталин лагерьлары турындагы югары кимәлле әсәрләре белән танышканнан соң да, ул чор турында тагын ишетәсе, шул җәфа-михнәтләрне кичергән кешеләрнең башларыннан үткәннәр турында күбрәк беләсе килә иде. Аяз абый, бик теләмәсә дә, тоткынлык чоры турында бер тапкыр үз фикерләре белән бүлеште.

– Ни өчен Сталин һәм аның сатраплары күбрәк зыялыларны, аеруча язучыларны юкка чыгарырга омтылганнар? – дигән примитив соравыма, иренмичә, аңлатмасын бирде.

– Һәр милләтнең рухын саклаучы, уйландыручы, яшәү мәгънәсен билгеләүче, күңелләрдә өмет рухы кабызучы ал-

дынгы, изге затлары була. Шуларның алгы рәтендә язучылар, кеше аңына сүз аша тәэсир итүчеләр тора. Өстә утыручылар, каләм осталары юкка чыгарыла барган саен, халык милли йөзен, телен югалта, зәгыйфьләнә, каршы тору рухы (оппозиция) сүнә, сүрелә килүне аңлыйлар. Татарның, билгесез мәнфәгатьләрне яклап, «батырлык» үрнәкләре күрсәтүе буйсынучанлыктан, хәтта куркаклыктан килә. (Искә төшерегез: безнең хәзерге милли халәтебезне Мәһдиев тә шулайрак бәяләгән иде).

Буйсынган милләтләрнең 1941–1945 еллар сугышына мөнәсәбәтен чагылдырган мәзәк тә бик урынлы китерелде.

– Командир окопта яткан солдатларына атакага күтәрелергә әмер биреп, «орлы, вперёд!» дип кычкыра. Урыс, татар, чуваш, башка милләт вәкилләре алга ыргыла. Күбесе сугыш кырында ятып кала. Яһүдләр траншеяда качып калалар, «сез ник атакага бармадыгыз» дип сорагач, «мы ведь не орлы, а львы, а львам команды не было» дип аңлаталар.

Фикерен «нәзари» яктан раслаганнан соң, ул беркадәр «тегендә» күргәннәренә тукталып китте. Ниләр генә кичермәгән, нинди генә түбәнлекләргә дучар ителмәгән икән татар язучысы. Аяз ага ачылып китә дә, ашыгыч эше исенә төшкәндәй, туктап кала, «чыдадык, түздек, барысын җиңеп чыгарга мәҗбүр булдык» дип, сүзне җиңелрәк мәүзугъка күчерә. Гәпләшүебез барыбер күбрәк милләт, әдәбият, сәнгать елгасына килеп чыга.

– Башка милләткә буйсынып яшәгәндә, халыкның рухы зәгыйфьләнә, әдәбиятның биле сына, – диде ул минем «безнең әдәбиятка нинди тышкы сәбәпләр үсәргә ирек бирми?», дигән соравыма.

– Ни өчен шундый көчле, дөньяны дер селкетеп торган коммунистлар фиркасы юкка чыкты?

Бу соалемә ул шаяртып җавап бирде:

– Партияне мактауда яңа җөмләләр, чагыштырулар табуы кыенлашкан иде. Шуңар да ул мәтәлде.

– Нәрсә ул патриотизм?

– Ул – үзеңне, рухыңны, аннан соң якыннарыңны ярату, дигән сүз. Ләкин аның мәгънәсен, эчтәлеген боздылар.

– Туган илне ярату түгелме соң инде ул?

– Аны яратмаска өйрәттеләр. Ә туып үскән, тәпи-тәпи йөргән җирне яратмый мөмкин түгел.

Туксанынчы еллар ахырында – яңа гасыр башында үзәктән иңгән сәясәтнең мәгънәсен, асылын ул тәгаен ачып бирде.

– Иманыбызга, динебезгә, телебезгә каршы бик астыртын, мәкерле, әйтергә кирәк, акыллы сәясәт алып барыла. Аны әүвәл тиле-миле булып кыланган, чынлыкта хәйләкәр Жириновский кебек рупорлар авызыннан әйттерәләр, аннан соң тормышка ашыра башлыйлар.

Аяз абыйның иҗади дуслары белән беррәттән, бакчачы, балыкчы, бергә ял иткән аркадашлары да җитәрлек иде. Җитмешенче еллар башында Идел буена гына урнашкан, Займище дип аталган төбәктән зыялыларга бакча урыннары бүлеп бирделәр. Шундый бәхеткә тарган кешеләр арасында драматург Т. Миңнуллин, Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Шәрәфетдинов, «Чаян» журналының баш мөхәррире А. Яхин һәм А. Гыйләҗевлар да була. Бу шәхесләрне уртак кайгылар, уртак шатлыклар һәм үзенең балыклары белән Идел елгасы якынлаштыра. Балык тотуларының мәзәкләре турында А. Гыйләҗев та, Т. Миңнуллин да язып чыктылар. Идел буенда йөргәндә, көймәдә йөзгәндә генә түгел, башка җәһәтләрдән дә Аяз абыйның «мин берәүдән дә ким түгел, була да алмыйм» дигән үҗәт, көнче холкыннан юмористлар бик оста, кызык хәлләр китереп чыгаргаладылар. Шуларның берсен А. Яхин уйлап таба. Әле бакчаларда кыяр өлгереп җитәргә иртәрәк бер вакытта, базардан сатып алып кайта да, иренмичә, һәр кыярын сабакларга бик нечкә җеп белән бәйләп куя һәм күршесенең – Аязның «хәлен белергә» юнәлә.

– Хәлләрең ничек, Аяз?

– Аллага шөкер, парин, озак еллар шулай булып торсын!

– Кичке ашыңны ашадыңмы әле? Өлгермәгән булсаң, миңа сугылыйк. Күрсәтәсе әйберем дә бар, – ди юморист, борынын ике тапкыр тартып, кул янтаулары белән чалбарын күтәреп алганнан соң. Сөйләшә-сөйләшә, А. Яхинның бакчасына керәләр. Хуҗа кеше, җәһәт кенә бөгелеп, «күршене яңа өлгергән кыяр белән кунак итик әле» дип, сөйләнә-сөйләнә, күрсәтә-күрсәтә, бакча нигъмәтләрен «өзеп-өзеп» ала.

Шуны карап торган кунак бер кызара, бер карала, Альберт кулыннан кыярларның берсен тартып алып, йөгерә-атлый үз дачасына таба китә. Бакчасына керә-керешкә, Аяз ага күтәрелеп бәрелеп дулаган, хатыны белән әнисен «сез, әрәмтамаклар, икәүләп җәй буе бакчада ятасыз, кешенең әнә кыяры өлгергән, сезнең бер нәрсәгез дә үсми» дип, кич буе, тамаша авторы кереп тынычландырганчы, дулаган, ди.

Үләренә берничә ай калгач, А. Гыйләҗев белән соңгы тапкыр, Татарстанның Дәүләт советы депутаты, Мәһдиев искә алып узган Фалис Вәлиевнең фатирында, тар мәҗлестә күрешеп калырга насыйп булды. Хәле бик авыр булып, Нәкыя ханымга таянып кына йөри алса да, дустының чакыруын кабул итеп, үзен җиңеп, очрашуга килгән иде ул. Минем анда булуымның сәбәбен әйтеп китү дә кирәктер. Без – Фалис Әхәт улы белән якташлар, Норлат районының Кычытканлы дигән сәер исемле авылында туып үстек, бергә мәктәптә укыдык, ул комбайнда эшләп, армия сафларын бизәп, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кергәндә, мин шул ук уку йортында ассистент вазифаларын башкарып йөри идем инде. Югары белем алганнан соң, аның карьера үсеше гаҗәеп тизлек белән барды: әүвәл Зәй районы Югары Пенәче авылында гади укытучы, шул ук мәктәпнең директоры, шунда урнашкан колхоз рәисе, районда партия контроле җитәкчесе, райисполком рәисе, берничә чакырылыш халык депутаты, атаклы «Зәй» совхозы директоры. Һәр эшендә үзеннән соң изге гамәлләр, ике катлы мәктәп бинасы, заманча фермалар, йортлар төзеп калдырды Фалис дус! Сайлаучыларының теләсә нинди катлаулы сорауларын канәгатьләндергәне өчен рәхмәттән башканы таләп итми. «Фатих Әмирхан иреннәре» арасыннан «кешеләргә ярдәм итү – депутатның, җитәкченең бурычы» дип кую һәм зәңгәрсу-соргылт күзләрендә хәйләкәр елмаю биетү белән чикләнә.

Эше һәрдаим муеннан булып, көне-төне кырда чабу, кешеләрнең гозерләрен үтәү белән шөгыльләнү сәбәпле, агымдагы татар әдәбиятын гел укып бара алмаса да, аның әйдәп баручы олы шәхесләренә Фалис һәрдаим игътибарлы булды. Җөмләдән, олуг язучыларыбыз Мөхәммәт Мәһдиев белән Аяз Гыйләҗевкә ихтирамын яшермәде. Әлеге затлар Тукай

премиясен алгач та, Татарстанның халык язучысы дигән исемгә лаек булгач та, аларны бүләге һәм тәмле сүзе белән, Зәйдә яшәсә дә, беренчеләрдән булып Ф. Вәлиев котлады.

Аяз аганың элегрәк сөйләгәне, кырмавык кебек, хәтердә ябышып калган.

– Яшәү өчен Зәйгә күченеп килгәч, күңелсез булыр, дип уйлаган идем, парин. Фалис Әхәтович, моңланып, Казанымны сагынып утырырга бирмәде. Рухи бушлыкны, Туфанны, Мәһдине, Гарифны сагынуларымны игътибары, юморы, көлүе белән берүзе тутырды. Суыткычны буш тотмады. Иртән эшкә барганда, хәлне белеп сугылыр, кичен, шайтан сулы шешәсен кыстырып, иркенләп гәпләшеп утырырга килеп керер.

Аяз ага Казанга әйләнеп кайткач, Фалис та даими депутат эшенә Казанга күчте. Биредә дә, Аяз абыйның фани дөньядагы соңгы көннәренә чаклы, алар аралашып, дустанә яшәделәр. Сөйләшендә урам сүзләрен, тозлы-борычлы юморны кыстырып сөйләргә яраткан Фалис өлкән дусты янында тәртипле, итагатьле кешегә әйләнә дә куя, КДУның татар бүлеген «тәмамлаган» пишкадәм диярсең.

Мөхәммәт Мәһдиевкә мөнәсәбәте шулай ук игелекле һәм җылы булды.

Мөгаллиме белән якыннан аралашып яшәүне Фалис үзе өчен мәртәбә санады, аңа төрлечә, бигрәк тә матди ярдәм итеп яшәргә тырышты.

Соңгы очрашу вакытында Аяз абый ашамады да, эчмәде дә, тирәнгә баткан моңсу күзләре белән карап, без шау-гөр килгәнне тыңлап кына утырды. Аяз Мирсәет улы турындагы истәлекләр зиһендә өзек-өзек кенә саклана шул. Аның төрле елларда, төрле дәрәҗәдә очрашуларда әйткән сүзләре, фикерләре заманында кәгазьгә теркәлеп барылмаган, онытылганнары – әһәмиятсез, икенче, өченче дәрәҗәдәгеләре булгандыр, дип кенә үзеңне юатырга кала.

Аяз Гыйләҗев үзеннән соң төрле жанрларга караган гаҗәеп зур әдәби мирас калдырды. Бу байлык әле чын-чынлап өйрәнелмәгән. Бу очракта аның тормышының икенче бер күркәм сыйфатына игътибар юнәлтү мөһим. Ул бериш сәнгать әһелләре, шул исәптән язучылар кебек, «гаиләлә-

ребез тулы, балаларыбыз күп булса гына милләтне саклап була» дип, акыл сатып кына йөрмәде, шәхси яшәеше белән үрнәк күрсәтеп, милли җанлы, һәркайсы үз өлкәсен сөреп барырлык өч ир-егет, өч бөркет үстереп калдырды. Аларны да рәсемгә төшереп, өч әдибебез үрнәгендә, «өч баһадир» дип атап булыр иде. Нәкыя ханым КДУның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем эстәп йөргәндә туган олы улы Искәндәр – хәзер тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан фәннәр академиясенең әгъза-мөхбире, икенче улы Мансур – драматург, «Бичура», «Баскетболист», «Казан егетләре» һ.б. заманча фикерләүле, үзенчәлекле әсәрләр авторы. Аны тамашачы да, укучы да үз өслүбен, үз иҗат алымнарын тудырган язучы, дип бәяли. Өченче улы белән танышлыгыма мактана алмасам да, анысын шактый уңышлы эшмәкәр дип ишетеп беләм. Шактый гыйбрәтле туйдан башланган гаилә мул уңышы белән дә сөендерде. Балаларына хас талант, дәрт, куәт, иҗади эшкә сәләт Аяз абыйдан килсә, тәрбия, әхлак, халкыңа мәхәббәт, тормышны алып баруга, татар һәм башка телләргә өйрәтү Нәкыя ханым җилкәсенә төшә. Төп игътибарын балаларына һәм пырдымсыз иренә бирсә дә, бергә укырга кергән көндезге төркемнән аерылмыйча, хәтта «хәерче» студентларга матди ярдәм күрсәтеп, бурычка акча да биреп торып, өлгерештә дә калышмыйча, әйткәнемчә, безнең белән бергә дипломын да алды Нәкыя ханым. Ир белән хатын үзара туган лөгатьләрендә аралашса гына, балалары шул ук телдә сөйләшә. Икенең берсе татарчаны ярым-йорты белеп, араларны «ачыкларга» туры килгәндә, русчага күчкән гаиләләрдән татар теленең нечкәлекләрен белгән, халкына турылыклы кеше сирәк чыга, милли әхлак, көнкүреш үзенчәлекләре, өлкәннәргә ихтирам, ата-ана алдындагы бурыч кебек сыйфатлар күңеленә сеңми. Аяз ага, карлыкканрак тавышы белән «милләткә өч егет үстереп бирәм» дип, Ахунов, Мәһдиев, Фәйзуллин кебек дуслары янында күкрәк кагып мактанып утырганда, татар теле һәм әдәбияты укытучысы, тыйнак Нәкыя ханым балаларына Тукайның «Туган тел»ен җырларга өйрәтеп, «Су анасы» белән «Шүрәле»не укып, аталарының абруен күтәреп, улларын бакты, өй эшләрен башкарды. Нәкыя ханым теләсә кайсы редакциядә журналист,

редактор, тагын әллә кем булып менә дигән итеп эшли алыр иде. Мәгәр ул мәктәпне ташламады, татар телен, әдәбиятын укыту методикасын камилләштерүгә багышланган үткен-үткен мәкаләләр дә бастырды. Моның төп сәбәпләреннән берсе – укытудан алган тәҗрибәсен үз гаиләсе әгъзаларына сеңдерү, балаларына рухи яктан да якынрак булуга омтылу, дип аңлатыр идем.

Татар милләте, төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә, сан ягыннан кими, телен югалта барган киеренке чорда үз халкының язмышы өчен җанатып йөргән өч бала тәрбияләп үстергән өчен генә дә Аяз абый белән Нәкыя ханым – мактауга вә соклануга лаеклы олы затлар.

Язучы үзе үлгәннән соң, мирасы турында кайгыртучылары булганда гына, аның исеме, даны яши. Язучының исеме әйләнештән төшеп калмау талантына, варисларының игътибарына, җәмгыятьнең үсеш дәрәҗәсенә бәйле. Аяз ага бу яктан да бәхетле булып чыкты. Кадерле ирен югалтканнан соң, Нәкыя ханым, чын-чынлап, А. Гыйләҗевнең мирасын, бигрәк тә публицистикасын, әдәби тәнкыйтен барлау, өйрәнү, популярлаштыру шөгыленә керешә, туктаусыз мәкаләләрен бастыра, мәктәптә музей ача. Язучы үзе исән чакта басылмаган язмаларын, хатларын җәмәгатьчелеккә ирештерә. Фәнни әдәби аңлатмалары чын библиограф, тәнкыйтьче дәрәҗәсендә башкарылган булулары белән сокландыралар. Безгә, укучыларга, Аяз Гыйләҗев язмышыннан яхшы мәгънәсендәге көнләшүдән башка нәрсә калмый.

***Ринат Мөхәммәдиев***

## Аяз Гыйләҗев әле дә безнең арада…[1]

Безнең өчен ул «Аяз абый» иде… Юк-юк, классик та түгел, лауреат та түгел, президиумнарга да чакырмыйлар иде кебек әле аны, хәтта тәнкыйтьчеләр дә, аның теге яисә бу әсәрен анализлаганда, шактый озак кына «кайбер кимче-

[1] Мөхәммәдиев Р. С. Аяз Гыйләҗев әле дә безнең арада… // Аяз Гилязов и его наследие в мировой и отечественной культуре / под ред. М. М. Хабутдиновой.– Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2018.– 131–138 б.

лек»ләренә туктала, дөресрәге, тырнак астыннан кер эзләп тәм таба торганнар иде. Тәкыйтьче халкы шундый, аларның бик сирәкләрендә генә әдәбият кайгысы була, ә күпчелек дәрәҗәлерәк авторларга ярарга тырыша, теге елларда «абкум» белгечләре» ди идек без аларны. Аларда Аяз Гыйләҗев кайгысы идемени! Тагы шунысы да бар, татар прозасында Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, М. Әмир, Ә. Еники, Ф. Хөсни, Ш. Маннур һәм А. Расихлар актив иҗат иткән 70 нче еллар иде бит.

...1976 елда мине, Фәрваз Миңнуллин тәкъдиме белән, «Казан утлары» журналының баш редакторы Зәки Нури үзенә чакырды. Әдәби тәнкыйть бүлеге мөдире Фәрваз Миңнуллин, Гариф Ахуновның урынбасары буларак, Язучылар берлегенә эшкә күчә икән, аның урынына лаеклы алмашчы эзләүләре. Мин эшсез түгел идем, «Коммунист Татарстан»а журналында белер-белмәс урыс телем белән фән бүлеген җитәклим, хезмәт хакым бермә-бер артыграк.

Зәки абый партизаннарча җылы каршылады, хәтта коньяк тәкъдим итте. Без сөйләшеп утырганда, ишекне шакыдылар, кабинетка язучы Аяз Гыйләҗев килеп керде. Яңа тәмамлаган әсәрен китерүе икән.

– Да, парень, Зәки, син үзең кебек озын егет тапкансың икән бит. Безнең кебекләрне якын да җибәрмәссез инде журналга,– дип әйтеп куймасынмы үткер телле әдип.

– Әле бит хәл ителмәгән, озынрак түгелме, дип икеләнеп утырам үзем дә,– ди Зәки Нури.

Аяз Гыйләҗев ялт кына мине кулымнан тартып китерде дә кабинет уртасына бастырып куйды, «кил әле, Зәки, син дә кил» дип, баш редакторны да чакырып китерде һәм аны аркама терәп бастырып куйды. Буй үлчәшәбез... Ә үзе ялт кына урындык өстенә менеп басты, безнең буйны тикшерә.

– Ярты сантиметрга, юк, бер сантиметрга, Зәки хәзрәт, син озынрак икән,– дигән нәтиҗә чыгарып куйды ул. Кыяфәте җитди...

Шулай итеп, барыбызның да күңеле булды. Зәки абый миңа Аяз абый култык астына кыстырып килгән папканы тоттырды.

– Менә Аязның бу әсәрен бүген үк укып чык. Иртәгә «журналда басарга ярамый» дигән нәтиҗә чыгара алсаң, эшкә алабыз,– диде ул.

Соңыннан, Зәки Нури белән хушлашып чыгып барганда, Аяз абый миңа хәйләкәр генә елмаеп күз кысып куйды: «Син Зәкидән 2 см га озынрак икәнсең»,– диде. Якыннан танышуыбыз шул көннән башланды кебек.

Озак та үтмәде, Зәки Нури мине үзенең урынбасары итеп билгеләде һәм проза, тәнкыйть, тарих һәм драматургияне башы-аягы белән миңа тапшырды. Менә шул елларда, моңа кадәр уңай герой, хезмәт кешесе образларын күрсәтүне беренче чиратта күз уңында тоткан журналда Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Мөхәммәт Мәһдиев, Мәхмүт Хәсәнов һәм, әлбәттә инде, Аяз Гыйләҗев әсәрләренә киң юл ачылды. Алар яңа язган әсәрләрен ничек һәм кайчан бастырырга дигән борчудан азат иделәр. Турыдан миңа китерәләр... Бу мактану булып аңлашылмасын, чынлыкта шулай иде. Ә Зәки Нури һәм аңардан соң баш редактор булып килгән Ренат Харис миңа һәрчак зур ышаныч белән карадылар. Бүген горурланып әйтә алам, «Җомга көн, кич белән...» һәм «Әтәч менгән читәнгә» повестьларын редакциягә китергәчтен, Аяз абыйның: «Боларны беренче булып укучы син буласың, парень...» – дигәне әле дә колак төбемдә яңгырап тора. Бу – зур ышаныч иде минем өчен.

Шул урында әйтергә тиешмендер: «Парень, син үзең проза язып карамыйсыңмы, яз әле...» – дип, миңа иң беренче булып киңәш бирүче һәм канат куючы да Аяз абый булды. Һәм беренче тәнкыйтьчем дә ул иде.

Аяз Гыйләҗев, әсәреңне укымый гына мактаучы яисә юкка чыгаручылардан аермалы буларак, яшьләр иҗатына гаять таләпчән һәм ихтирамлы остаз булды. Бу өлкәдә аңардан фидакяррәк татар әдәбиятында башка берәү булдымы икән! Булса, шигърият өлкәсендә, мөгаен, Илдар Юзеев кына аңарга тиңләшә алгандыр. Әсәрең бар икән – бар, юк икән – юк дип, уңга-сулга карамый кистереп әйтә белгән шәхес иде Аяз абый. Эх, бүгенге татар әдәбиятына, яшь һәм башлап язучыларга Аяз Гыйләҗев җитми, дип уфтанасы килә

кайчак. Күпме зәвыксызлык, буш сүз, уртакул язмалар аяк астында буталып йөрмәс иделәр.

...Дистә еллар буе Татарстан Язучылар берлегенең кабул итү комиссиясен җитәкләде Аяз абый. Таләпчәнлектә аңарга җиткән булмас!.. Татар әдәбиятының югары дәрәҗәсе аның өчен бар нәрсәдән дә кадерлерәк иде. Күпме кеше бүген аны үзенең остазы саный, берсе өчен дә йөзе кызармас иде, әгәр бүген арабызда булса. Кызганыч, соңгы араларда бу таләпчәнлек юкка чыкты. Гомумән, әдәбиятта гына түгел, мәдәниятебезнең һәр өлкәсендә югары зәвыкка нигезләнгән таләпчәнлек җитми бүген. Тел бетә, китап укымыйлар, әдәбият һәм сәнгать әсәрләренә ихтыяҗ кими, дип лаф орабыз. Ә бит төп бәла таләпчәнлек югалуда, сүз иреген – кем ни язса, шул басылырга һәм укучыга тәкъдим ителергә тиеш, дип аңлауда, демократияне «вседозволенность» дип кабул итүдә. Театрда да, аеруча җыр һәм эстрадада, телевидение һәм радиода... Кыскасы, кая карама зәвыксызлык һәм уртакуллык гөрләп чәчәк ата бүген... Аяз Гыйләҗев җитми, үткер һәм туры сүзле Аяз абый...

...Аяз абыйлар белән без күршедә генә диярлек яшәдек. Еш кына Нәкыя апа белән Аяз абыйда кунакта да булырга туры килә иде. Татарның үрнәк гаиләсе менә кайда иде ул елларда. Аш-су һәм кунакка хөрмәт турында әйтеп тә тормыйм. Хәер, монысы да – татар халкының башкаларны сокландырган асыл сыйфатларыннан. Бала тәрбияләүдә аларга җиткән булмагандыр. Мин 7 ел язучылар берлегенең партия оешмасын җитәкләп, 10 ел рәислек итеп, һәр әдипнең ничек яшәве, гаилә хәле, тормыш шартлары белән таныш идем. Яхшы гаиләләр бар иде, күп иде, әмма балалар тәрбияләүдә Аяз абый белән Нәкыя апага җиткән булмагандыр. Алар таләпчән дә, кайгыртучан да, кирәксә – кырыс та була белделәр. Шәһәрдә туып-үскән егетләр һәрчак ана телендә сөйләште, укый һәм яза да белделәр...

Малайлар кайда һәм кем белән аралаша, кем булырга хыяллана, нинди мавыгулары бар – барысы да мөһим иде алар өчен. Укытучыларга, улларының остазларына аеруча зур хөрмәт иде. Бу гаиләдә Миркасыйм Усманов, Марсель Сәлимҗанов аеруча зур авторитет санала иде, ялгышмасам.

Искәндәр белән Мансурның киләчәк юлларын билгеләүдә бу – һәлиткеч роль уйнаган булса кирәк. Рашат бүген кем булып эшлидер, белмим... Әмма минем күз алдында үскән бу егет, иманым камил, кайда гына эшләмәсен, ата-ана йөзенә кызыллык китерә торган булмас.

...Аяз абый көн-төн язу өстәле артында утыра алган язучы иде, кирәксә, тәүлектә 24 сәгать эшли ала торгандыр кебек иде ул. Иҗат йортларында әле дә аны искә алып, сагынып сөйлиләр. Мәскәүдә В. Распутин, Виктор Астафьев... Башкорт әдипләре... Барысының да кат-кат сорашканнары булды миннән. Үз әсәрләре генә түгел, башкаларга ярдәм итү, редакцияләү, кирәксә, хәтта кеше өчен язып, очын-очка ялгаудан да баш тартмый торган иде ул. Әйтик, И. Салаховның «Колыма хикәяләре»н матбугатка әзерләүдә, Миргазыян Юнысның беренче повестьларын камилләштерүдә, Газиз Кашаповка киңәшләр бирү юлында күпме көч куйганлыгын «Казан утлары» һәм китап нәшриятында ул елларда эшләгән кешеләр яхшы хәтерли булса кирәк.

...Аяз абый, М. Мәһдиев, Г. Ахуновлар белән Татарстанда без булмаган берәр район калдымы икән ул елларда? Ә районнарга, халык арасына чыгыйк, дисәң, кырык эшен кырык якка ташлап торырга әзер иде ул һәрчак. Еш кына халык арасына бер машинада (рульдә үзем булган чаклар да еш иде) шофёр белән дә чыгып китә идек. Юл буе шаянлык, уен-көлке, нечкә һәм урынлы итеп төрткәләшеп алулар... Һич онытылырлык түгел. «Гариф әкә...», «Мөхәммәт дус...», «Әмирхан морза...» дип эндәшүләре генә ни тора иде бит аның!

Тыныч кына барганда: «Э-эх, егетләр, карагыз әле, бу дөньяның матурлыгын күрегез әле сез... Кояш батып килә... Көтү кайта бит... Күрегез әле, күр... Яшь килен судан кайтып килә...» – дип, чын күңелдән сокланып куя иде ул...

Йә булмаса, тыныч кына уйланып барган җирендә: «Э-эх, Ринат Сафиич булырга иде ул хәзер...» – дип куяр иде. Мин моны аңламый идем башта, хәтта, күңелемнән генә үпкәләгән чакларым да булгандыр... Бу – аның тормышка бетмәс-төкәнмәс мәхәббәте ташып чыгу булган.

Табигать матурлыгына, яңа көнгә, яшьләргә сокланыр иде Аяз абый. Татарны, халыкны үзенчә күрә һәм ярата белә торган иде...

Аның белән һәрчак күңелле. Ул – фантазёр... Һәрчак хәрәкәттә, янәшәдәгеләргә дә күңелсезләнергә ара калдырмый... Балтач районы Чәбия авылы культура йортында кемнеңдер килгәнен көтеп торабыз берзаман. Баш очында «Три богатыря» рәсеме эленеп тора. Мәһдиев, Ахунов һәм үзенең шул рәсем каршында шул ук кыяфәткә кереп фотога төшүләре дә – аның идеясе... Соңрак бу фото рәссамнарны да кызыксындырды... Кайберәүләр үзләренә үпкәләп тә йөрде әле: «Нигә алар өчәү, ә без алардан кимме, без дә баһадир ич?» – дип әйтәселәре килде кебек...

Мәҗлесләрдә, концертларда җыр ярата... Иң яратканы – «Олы юлның тузаны»... Аны, кем җырлавы һәм ничәнче кат җырлавына да карамастан, тыныч кына тыңлый алмый иде.

Олы юлның тузанын ла, үзем күрдем тузганын,
Белми калдым, күрми калдым яшь гомернең узганын...

Шыпырт кына башын читкә борып, күз яшьләрен сөртәсөртә тыңлаганын хәтерлим, ышанасызмы-юкмы, шыңшыпшыңшып елаган чаклары да була торган иде...

Аеруча Хәйдәр Бигичев җырлаганда...

– Тагы бер җырла әле, Хәйдәр...– дия торган иде.

– Юк җырламыйм, юкса Аяз абзыкай елый бит. Аны елатасым килми,– дип шаярта иде Хәйдәр.

Аяз абый җырчы булмаса да, үзе дә кушылып, үзалдына җырларга ярата торган иде...

...Тагы бер яктан уникаль язучы иде Аяз абый. Аның хатлары... Кая барса да, аеруча иҗат йортларына киткән чакларында, якын аралашкан каләмдәшләренә, дусларына хатлар яза торган иде ул. Эчкерсез уйлары, фикерләре, кешеләргә объектив бәяләре – шул хатларда. Миндә дә аның җиде-сигез хаты саклана. Җидешәр-сигезәр биткә сузылганнары да бар... Ул сагына, хөрмәт итә, яшәүнең матурлыгын, кадерен белә иде. Хатлары бүген дә шул хакта сөйли.

Әйткәнемчә, замандаш рус язучыларын – Распутинны, Астафьевны, Василий Беловларны ярата, югары бәяли иде. Ә Чыңгыз Айтматов – аеруча яратып укыган язучысы бул-

ды. Аның үзен дә «Безнең Аяз абый...» дип, шулар исемләгенә кертеп сөйләшкән чакларыбыз бар иде. Әмма Мәскәүдә дан-дәрәҗә кайдан булуыңа карап бүленгән еллар иде, «автономияле республика»дан, Татарстаннан ул югарылыкка күтәрмәделәр. Аннан бит әле теге тәмугтагы «ачык казан» турындагы анекдот та бар. Көнчелек, хөсетлек, тар күңеллелек алга чыгарга бирмәде татар язучысына...

...80 нче еллар уртасында СССР Язучылар берлеге съездында, Мәскәү кунакханәсендә, ничектер, очраклы рәвештә без бер төркем татар язучылары Айтматов белән бер лифтка туры килдек. Шунда Аяз абый татарлар турында, Айтматовның әнисе татар булуы хакында сүз кузгатты. Ә Айтматов, исе китми генә: «Мин – кыргыз язучысы»,– диде дә, безне калдырып, кырт борылып китеп барды. Аяз абый ник эндәштем дигән көндә калды. Хәтта, җанын тынычландырып, бер сүгенеп тә алды үзалдына. Ә барыбер аның иҗатына хөрмәте сүрелмәде.

Мин бу хакта Ч. Т. Айтматовка Төркиядә очрашуларыбызның берсендә, 1995 ел иде кебек, сөйләдем. Безне еш кына бер үк оешма конференцияләргә чакыра торган иде. Истамбулда бер үк нәшриятта китапларыбыз чыккан чак. Ул мине игътибар белән тыңлады, әмма хәтерли алмады теге очрашуны. «Баш әйләнгән чак булгандыр»,– дип, үзен нык кына ачуланып та алды. Татар халкына, җир йөзендә иң кадерле кешесе булган Әнисен тудырган халыкка, чиксез хөрмәтен белдерде. «Мөмкин булса, миннән сәлам тапшырыгыз Аяз Гыйләҗевкә һәм гафуымны җиткерегез», – дип тә кат-кат үтенде. Һәм үзенең, русчага тәрҗемәләре аша, Аяз абый иҗаты белән таныш булуын да искәртте.

...Аяз абый минем Төркиядән килгән олы кунагым Туран Язган белән бик тиз уртак тел тапты. Гомумән, кеше белән ул бик тиз таныша, дуслаша торган иде. Соңыннан алар Нәкыя апа белән Туран Язган чакыруы белән Төркиягә дә бардылар... Нәкыя апа алдарга бирмәс, бик рәхмәтле һәм бәхетле булып кайткан иделәр. Аны әле булса сорашалар Төркиядә, хөрмәт белән искә алалар... Шушы уңайдан төрек кардәшебез, фидакяр дустыбыз Фатих Котлыга минем аеруча зур рәхмәтләр әйтәсем килә...

Гомумән, Аяз Гыйләҗев шәхесе, аның иҗаты кебек үк, масштаблы, игелекле һәм зур иде. Еллар үткән саен, аның масштаблы образы, мәһабәт шәхесе һәм кабатланмас иҗаты безнең күңелләрдә, халык хәтерендә олыгая, масштаблырак була бара һәм яңадан-яңа офыкларны яулавында дәвам итә...

Аяз Гыйләҗев әле дә безнең арада, безнең күңелләрдә яшәвен дәвам итә...

*2018*

***Искәндәр Гыйләҗев***

## Минем әтием Аяз Гыйләҗев

Бу сүзләрне яздым да озак кына уйланып утырдым. Аларның мәгънәсен нинди тирән, күпкырлы икәнен аңлау һәм хәтта үз-үземә аңлату өчен уйландым... Бераз каушау да бар, һичшиксез. Нәрсә уйландырды, нәрсә бигрәк тә каушатты соң? Әтием турында булган фикер-хатирәләремне беркайчан да әйтеп бетерә алмам, дип каушыйм, ахрысы. Әлбәттә, бу очракта сәбәп аның турында искә алырга теләмәүдән түгел, ниндидер дәрәҗәдә минем гаҗәеп олы җаваплылыкны үз өстемә аласы килми... Аяз Гыйләҗевнең шәхесе шулхәтле күпкырлы, масштаблы, тирән, каршылыклы – хәтерем үзенчәлекләреннән чыгып та мин аның турында тиешле дәрәҗәдә әйтә-сөйли алырмынмы икән, дип, үз-үземә сорау куям...

Шунысын да онытырга ярамый: табигый ки, әтиемә мөнәсәбәтем гаять дәрәҗәдә субъектив. Язучы Аяз Гыйләҗев кемгәдер коллега, дус, әңгәмәдәш, очраклы таныш булган, кемдер анда конкурент, хәтта дошман күргән, күпчелек өчен ул бай телле, талантлы, яраткан язучы гына булып кала. Ләкин минем өчен беренче чиратта ул – әти, мине тәрбияләгән, үстергән, җанының зур бер өлешен миңа салган, бүгенге көндә дә мин бик тә юксына торган кеше.

Тарих барысын да үз урынына куячак, һәр гамәлгә, һәр кешегә үз бәясен бирәчәк. Татар халкы, татар теле, татар мәдәнияте яшәсә, Аяз Гыйләҗев, һичшиксез, аның хәтерендә, шәхсән аның өчен генә билгеләнгән, уникаль бер урын алып торачак. Бу сүзләрне мин атасын бик тә яраткан һәм хөр-

мәт иткән Аяз Гыйләҗевнең улы буларак кына әйтмим, бу тормышта инде бераз тәҗрибә һәм белем туплаган кеше, тарихчы буларак әйтәм. Чөнки Аяз Гыйләҗев чыннан да бу сүзләргә лаек.

Ул гаҗәеп энергияле, тынгысыз, дәртләнеп, кабынып китә торган кеше иде. Инглизләрнең шундый бер гыйбарәләре бар: «self made man» – «үзен үзе ясаган кеше», ягъни бу тормышта бары тик үз көченә таянып яшәгән һәм юл тапкан кеше. Минем әти нәкъ шундый кеше иде! Бала чагыннан ук язучы булырга хыялланган, бала чагыннан ук язган. Аңа бу эштә беркем дә ярдәм итмәгән, арттан төртеп тормаган. Сугыштан соңгы авыр елларда ерак керәшен авылыннан Казанга килеп, Казанны яулап алуны максат итеп куйган, максатына ирешкән – татар халкының бөек, яраткан язучысына әйләнгән. Университетка укырга кергән, кулга алынган, яшьлегенең иң гүзәл елларын ГУЛАГ лагерьларында уздырган. Яңадан Казанга кайткан, гаилә корган, журналист булып эшли башлаган. Һәм язган, язган, язган...

Әгәр дә мин: «Һәр кешенең тормышы берничә хәлиткеч этаптан яки циклдан тора»,– дип әйтсәм, «Американы ачмамдыр», ихтимал. Ул этаплар аның формалашуында, аның үсешендә хәлиткеч роль уйныйлар. Шул циклларның төсен, эчтәлеген, әһәмиятен бары тик синең янындагы кешеләр билгели. Алар белән аралашу, хәтта алар белән янәшәдә яшәү, күңелдә, аңда җуелмас бер эз калдыра. Безнең янәшәбездә һәрвакыт төрле кешеләр пәйда булып тора. Кемдер югала, кем беләндер аралашуны көтелмәгән, чамаламаган сәбәпләр аркасында өзәсең. Һәм һәрчакта бу даирә кабатланмас, уникаль... Синең тирәңнән кайберәүләр бакый дөньяга күчә, кемдер әле исән чакта синең тормышыңда үзенең урынын югалта, алар синең күңелеңә якын булмый башлыйлар. Бу – мәңгелек әйләнеш. Ләкин шул ук вакытта синең белән гомерең буе бергә булган кешеләр дә бар. Физик яктан юк булсалар да, инде вафат булсалар да – алар барыбер синең белән. Эчтән генә алар белән киңәшләшәсең, аларга таянасың, аларны искә аласың. Андый истәлекләр җаныңның бер өзелмәс өлешен тәшкил итәләр. Әтием янәшәмдә

һәрвакыт фикердәшем, киңәшчем булды да, һаман да шулай булып калыр...

Балачак аерым мәгънәгә ия булган аралашулардан торса, олыгайгач, тыгыз аралашу даирәсе бөтенләй башкача була икән, дип әйтсәм дә ялгыш булмас: мәктәп, университет, аспирантура, фәнни эш белән шөгыльләнү еллары... Ләкин минем әтием, инде моннан егерме бер ел элек вафат булса да – ул һәрчак, һәр мизгелдә минем белән...

Әле һаман да берәр мавыктыргыч китап укысам, акыллы фильм карасам, кызык кеше белән танышсам – «эх, менә бу китапны әтигә укытырга, фильмны әтигә күрсәтергә, бу кеше белән әтине таныштырырга иде»,– дип, ихтыярсыз уйлап куям... Аның фикере ничегрәк булыр иде микән? Ул нәрсә әйтер иде? Нинди сүзләр табар иде? Һаман әти белән уртаклашасы килә, аның фикерен ишетәсе килә...

Шунысын да төгәл беләм – энеләрем Мансур һәм Рәшат нәкъ шундый ук хисләр кичерәләр. Бүгенге көндә бик еш очрашып торып булмаса да, без очрашкан минутларда әтине гел искә алып торабыз. Бер үзенчәлек – без күңелсезләнмибез, ә әтинең гыйбрәт алырлык гамәлләрен, мәзәкләрен, сүзләрен, шаяртуларын искә төшерәбез, бераз моңсуланып елмаябыз, көләбез – бу үзе бер мөһим тормыш тәҗрибәсе... Тормышка, дөньяга карашыбыз киңәеп киткән шикелле андый мизгелләрдә.

Әтиемнең кайсы сыйфатларын аерып искә алып булыр иде?

Аның эшчәнлеге, гаҗәеп сокландыргыч эшчәнлеге. Бала чагыбыздан ук безнең нинди дә булса эш белән мәшгуль булуыбызны тели иде, таләп итеп, шуңа ирешергә омтыла иде. Бер мисал. Безне өчебезне дә кимендә бер чит теленә өйрәтергә омтылды әтиебез. Совет заманында бу бик тә экзотик бер хыял булып кабул ителгәндер – дөньялар ябык, чит илләргә сәяхәт кылу бик сирәк кешегә генә эләккән «бәхет». Төгәлрәк әйткәндә, чит телләрне өйрәнү – чын мәгънәдә перспективасыз бер шөгыль булып тоела иде. Әти күрәзәче булган ахрысы... Ул башкачарак уйлаган... Ахыр чиктә аның бу хыялы һәм теләге минем тормышымда хәлиткеч урын ал-

ды – минем өчен алман телен өйрәнү, Алманиядә озак вакыт яшәп, фәнни эш алып бару мөмкинчелеген ачты.

Без уянганчы, ул эшенә алына, машинка тавышына без уяна идек. Минемчә әти беркайчанда чын-чынлап ял итмәде – бармаклары авырта башлаганчы, ул машинка артында утыра... Калган вакытта да барыбер язучының фикере кайный тора ич, ихтыярсыз ул уйланып йөри, аның башында туачак әсәрләр яши. Иҗади процесс, илһам дигән бик тә серле көч аны беркайчан да ычкындырмый, берничек тә җибәрми, бәйдә тота, әсир итә, хәтта эзәрлекли дип әйтер идем.

Бүген дә сокланып искә алам – әтидән дә күп китап укыган, төрле өлкәләрдә белемле яки хәбәрдар кешене белмим диярлек. Тарих, география, татар, рус, дөнья әдәбияты, сәнгать, сәяхәтләр – безнең бай китапханәбездә нинди генә китаплар юк иде! Шуларны барысын да әти игътибар белән укып чыккан, хәтерендә калдырган, алган белемен ул һәрвакыт тормышында һәм әсәрләрендә бик оста куллана иде.

Әти юмарт кеше булды. Эшчәнлеге кебек үк, аның юмартлыгы да чик белмәде. Биредә мин «юмартлык» сүзенең киң мәгънәсен кулланам. Кунак кабул иткәндә дә, яшь язучыларга булышканда да аның юмартлыгы ташып торды. Юмартлык, киң күңеллелек аңа кайвакыт кешеләргә объектив караш белән карарга, аларга объектив бәя бирергә дә комачаулый иде. Аны юмартлыгы ялгышларга этәргән чаклар да булгандыр. Кайберәүләрдән күңеле кайтты, кайберәүләр белән аралары өзелде, ләкин әтинең юмартлыгы һичвакыт сүнмәде – чөнки ул оптимист булды, кешеләргә, аларның яхшы сыйфатларына ышанып яшәде. Аның юмартлыгында да әтинең гаҗәеп каршылыклы шәхес икәнлеге ярылып ятты – характеры буенча шактый кырыс кеше, тормышның кайбер мизгелләрендә аның бала-чага кебек сентименталь, нечкә күңелле булып китүе – шуның дәлиле.

Минем уйлавымча, кызганыч ки, язучы буларак, әти беркайчан да чын мәгънәсендә ирекле кеше була алмады. Гәрчә язучылар арасында ул барыбер иң ирекле фикерләгән, яшәгән һәм иҗат иткән шәхесләрдән булса да. Бу парадокс түгел. Мохит, җәмгыять, тормыш шартлары аны шундый булырга мәҗбүр иттеләр.

Бер яктан караганда, Аяз Гыйләҗев – үткен телле, тапкыр, мөстәкыйль, туры, хәтта усал сүз әйтергә әзер язучы. Кайбер түрәләребез дә заманында аның кискен әйтелгән сүзләрен ишеткәләделәр. Шул сүзләр аны кайбер очракларда авыр хәлгә дә куйдылар. Ләкин әти үзен үзгәртмәде, үзгәртә алмады, үзгәртергә теләмәде. Үзгәртсә, ул Аяз Гыйләҗев булмас иде. Димәк, ул ирекле булган, дигән күзәтү ясарга мөмкин шикелле.

Икенче яктан, әти тормышында һәрвакыт ниндидер конкрет, төгәл кысаларда яшәргә мәҗбүр булды. Бу кысаларны инде мохит тудырды. Дәүләт, җәмгыять, партия аны «урынына утыртырга», төгәл билгеләнгән кагыйдәләргә буйсындырырга теләделәр. Ә ул – гаилә башлыгы, хатынын, балаларын үлеп яраткан ир. Гаиләне тәэмин итү, гаиләне алып бару – аның изге бурычы. Шуңа күрә дә ул шул уен кагыйдәләре каршында кайчак баш ияргә мәҗбүр булды: эчке дөньясы, җаны иреккә омтылса да...

Чын, җитди, мәгънәле әдәби әсәрләр иҗат итү өчен язучыга табигый сәләт кенә җитми икән. Язучы, өстәвенә, мөмкин кадәрле ирекле дә булырга тиеш. Аяз Гыйләҗевнең сәләте чын мәгънәдә кодрәтле, көчле! Аның каләменнән чыккан әсәрләр – XX йөз татар әдәбиятының горурлыгы, бизәге. Сәләтле кеше буларак, ул гомере буе максималь ирeклеккә омтылды, ләкин барыбер ирешә алмады. Минемчә, аның язучы язмышының төп каршылыгы да, төп фаҗигасе дә шул.

*2006*

*Мансур Гыйләҗев*

## Әтием[1]

Биш яшемдә чагында миңа коточкыч төш кергән иде: имеш, минем әтием үлгән, һәм аны җирләргә алып китәләр. Берничә көн дәвамында шул җанөшеткеч төш тәэсирендә аңгыраеп йөрүемне хәтерлим. Ятимлек сагышы нәни йөрәгемне учлап тоткан иде... Утыз алты елдан соң әлеге төш өнгә әверелде...

Бала чагымда әти минем өчен дөньяда иң көчле, иң матур, иң акыллы һәм кодрәтле кеше булып тоела иде. Бүтән балаларның әтиләре минем өчен гадәти бер «абзыйлар» гына... өстәвенә, мин сабый чагымнан ук, әни белән әбидән ишетеп, әтиемнең бөек татар язучысы икәнен һәм бөек әсәрләр иҗат итүен белә идем. Шуңа да әти язу өстәле янына утыруга, безгә кычкырып көләргә дә, фатир буйлап чабып йөрергә дә ярамый иде. Ул вакытта без Воровский урамындагы «хрущевка» ның кечкенә генә ике бүлмәле фатирында яши идек. Минем өчен һәр иртә язу машинкасының тавышы белән башланып китә. Әти таңнан торып ук эшли башлый. Мин хәзер бүтәннәрнең машинкада басуына колак салам, ләкин әти бармаклары кагылып дөньяга килгән ритмны мин ишетә алмам инде. Ул тавышның язмасын тыңлап, шул чагында дөньяга килгән юлларны укып карасаң, хәзер кызыклы һәм гыйбрәтле булыр сыман... Мине иҗат дөньясына чакырган музыка шикелле яңгырый иде машинка тавышы. Чыннан да, әтинең язу машинкасына мөнәсәбәте музыка коралына карата кебек иде – ул аны бик кадерләп саклый, пөхтә тота, хәтта холкын белә һәм аңардан беркайчан да аерылмый. Безнең гаиләдә, соңрак, язу машинкасына бәйле йола да пәйда булды. Искәндәр абыйга уналты яшь тулгач, әти аңа Югославиядә ясалган җыйнак кына машинка алып бирде. Шул ук яшьтә мин «Эрика» машинкасына тиендем. Рәшат энекәш тә, уналтысы тулгач, шундый ук бүләккә ия булды.

---

[1] Гыйләҗев М. Әтием // Аяз Гыйләҗев: Истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 71–76 б.

Минемчә, бу традиция әтинең яшьлегендәге яшерен хыялы белән бәйле иде: беренчедән, ул яза башлаган елларда машинкалы булу зур проблемалар тудырган, бик авырлык белән генә машинкалар сатып ала алган; икенчедән, улларының кайсысы булса да, бәлки, аның язучылык эшен дәвам итәр?.

Безне нәселебезнең борынгы гадәт-йолалары белән таныштыруга да әти зур игътибар бирә иде. Җәй саен без Зәй һәм Сарман районнарындагы авылларыбызга кайтып китәбез. Әти инде андагы якын туганнарга әйтеп куйган: балаларны җәлләп тормагыз, авыл эшләре кушыгыз, ипекәйнең тәмен белсеннәр! Әтинең зирәклегенә тора-бара шаккатам. Без авылда кыр эшләрендә дә катнаштык, яшелчә бакчасында да казындык, печән дә чаптык, утын да кистек, умарталар тирәсендә дә кайнаштык. Авылдагы әшнәләрдән берни белән дә аерылып тормый идек.

Безнең ыруда бала туу уңаеннан агач утырту гадәте дә бар. Аның мәгънәсен дә мин үсә төшкәч кенә аңладым: агач утырту белән син ниндидер күренмәс җепләр белән шул җиргә баглы буласың, аны үзеңнеке итеп ярата башлыйсың. Чишмәләрне пакьләндереп тору да – безнең нәсел өчен таныш йола. Әтиебез безне дә коеларны, кизләүләрне хөрмәт итәргә өйрәтте. Ә Сабан туе?! Безнең өчен бик тә үзенчәлекле бәйрәм иде ул. Бүтәннәргә Сабан туе – күңел ачу, мәҗлес кору, бәйгеләрдә катнашу булса, без исә бәйрәмнәргә тозлы кыяр, помидор тулы агач мичкәләр, кыздырылган көнбагыш тулы капчыклар төялгән арбага утырып барабыз. Сабан туенда бу арба үзенә күрә бер сәүдә үзәгенә әверелә. Хәзер мин шул тозлы помидорларны кабымлык иткән мәст ирләрдән көнләшеп куям. Безнең туганнар шулкадәр тәмле итеп тозлый белә иде аларны! Барысы да – үз бакчабыздан... Җитмәсә, безнең ише шәһәр малайларының да хезмәте кергән моңа. Янәшәдә генә кыз туганнарыбыз айбагыр сата. Безнең кебек ташбаш малайларга исә тирә-юньдәге буш шешәләрне җыярга кушалар иде. Миңа бу турыда язу һич тә оят түгел бүген. Аракыдан, сыра яисә лимонадтан шешәләрнең бушавын көтеп кызмача төркемнәр тирәсендә буталу кызык бер маҗара төсле истә калган. Кире кайтканда, безнең мичкәләр буш шешәләр белән тулы була... Эшмәкәрлек гадәте безгә, бәлки,

шул рәвешле сеңдерелгәндер. Бу исә авыр елларда ничек тә исән калырга тырышуга, хезмәт сөючәнлеккә барып тоташа.

Ыруыбызның бүтәннәрдән үзенчәлекле аерылып торуын: сәләт, йолаларга сыгыну, хезмәт сөючәнлек, пөхтәлек, сүздә тору җәһәтеннән гел үзебезчә булуын әтиебез һәрвакыт тәкърарлап тора иде. Ул моның белән горурланды, безне дә горурланырга өйрәтте. Бу горурлык хисе аның төп иманы иде.

Ул, кунакчыл кеше буларак, зур мәҗлесләр җыярга хирыс иде. Кунаклар бездә еш булды. Әни табынны бик мул кора, төрле ризыклардан өстәл сыгылып тора иде. Татар мәдәниятенең күренекле кешеләреннән бездә кем генә булмады икән? Шәриф Хөсәенов, Шәүкәт Галиев, Марсель Сәлимҗанов, Илдар Юзеев, Гариф Ахуновларны мин балачактан безнең өстәл тирәсендә утырган кыяфәттә хәтерлим. Әти безгә дә табын тирәсендәрәк утырырга куша – олылар сөйләшкән сүзләр колакларына керә торсын, дигәндер инде. Чыннан да, мәҗлестә утыру өчен дә үзгә бер сәләт, үзгә бер культура кирәк бит. Сүз гадәттә әдәбият-сәнгать, тарих тирәсендә әйләнә иде төсле. Татар халкының үткәненә һәм киләчәгенә бәйле мәсьәләләр дә күтәрелә иде. Андый мәҗлесләр вакытында сеңдерелгән дәресләрне дөньяның бернинди университетларында да алып булмый. Әлбәттә, без биредә тын гына, дәшми генә утырырга тиеш идек. Бу – шулай ук бик борынгы мөселман гадәте. Дөньяның мөхтәрәм кешеләре, аксакаллар сүз алганда, яшь-җилкенчәккә аларның һәр фикерен эләктереп калу ләзем. Мин бу зарурияtne дә соңыннан аңладым, билгеле. Хәзер үземнең дә кайбер фикерләрне әйтү ихтыяҗы барлыкка килде дә... Тик андый кичәләр кабатланмый икән шул.

Әйе, безне балачактан ук дәшмәскә һәм үз фикерләребезне сак кына әйтергә өйрәттеләр. Моның төп сәбәбе без үскән елларга гына түгел, без туганчы булган чорларга барып тоташа. Ул заманнардагы фаҗигаләр турында хәзер укып беләбез. Безнең нәселгә исә аерата нык кагылган әлеге большевистик афәт. Әти ягыннан (әтиемнең бабасы) Сәхабетдин бабай – Сарманның җәмигъ мәчете имам-хатибы – утызынчы елларда Алабуга төрмәсендә атып үтерелгән. Әни ягыннан (әниемнең әтисе) Илһаметдин бабай исә Бөгелмә зинданын-

да кырыгынчы елларда юкка чыга. Бөтен туган-тумачаның диярлек мөлкәте тартып алына. Үз фикерләрен курыкмыйча әйтергә җөрьәт иткән әти исә үзенең иң матур яшьлек елларын Сталин лагерьларында үткәрә. Күрәсең, әти дә, әни дә үз улларын гыйсъянчы итеп – коммунистик лагерьларның киләчәктәге тоткыннары итеп тәрбияләргә теләмәгәннәрдер... Бәхетебезгә, андый заманнар үтте шикелле...

Без балачактан ук татар театрларындагы бер генә премьераны да калдырмый идек. Жанрына, сыйфатына карамастан, әти безне һәр спектакльгә алып бара иде. Шулай да, сиземләү кимәлендә, без аларны аңлап карый идек сыман. Аннары бит театрны залдан гына түгел, эчтән дә – баш режиссерның кабинетыннан алып актерларның гримеркасына кадәр – күзәтү мөмкинлегенәэия идек. Ләкин иң гаҗәбе – әтинең премьералары. Чөнки аларның һәрберсе бәйрәм банкетлары белән төгәлләнә. Бу – үзенә күрә театр традициясе. Гадәттә, ул мәҗлесләр йә безнең өйдә, йә дачада үтә. Менә шунда инде спектакльне энәсеннән-җебенә кадәр тикшерү башлана. Безнең өчен кызык та, гыйбрәтле дә: яңа гына актерны сәхнәдә рольдә карадык, хәзер ул безнең өстәл янында гап-гади кеше кебек утыра, әни пешергән пәрәмәчне ашый!

Табигый, без театрны бик тә ярата идек, аның могҗизасы каршында хәзер дә баш иябез. Мең рәхмәт әтиебезгә!

Күп язучылар йөрәк сырхавыннан җәфаланалар. Әтине дә яшьтән үк йөрәге борчый иде. Шуңа да, бер табибның киңәше белән, ул балыкчы булырга карар кылды. Балыкчылык корты бер җанына керсә, бүтән чирләр бер якта торсын! Шуннан Идел буенда җыйнак кына матур дачабыз пәйда булды, әти моторлы көймә сатып алды. Әти балыкчылык шөгыленең фанатигына әверелде, без дә аңардан калышмый башладык. Малай-шалай өчен аннан да илаһи бәхет бармы соң? Иртә таңнан көймәдә Иделнең аулак култыкларына керәсең, якорь саласың да кармакны үзең генә белгән сихер сүзләре белән суга ыргытасың... Гаҗәп, шуннан соңгы елларда әти йөрәгеннән беркайчан да зарланмады.

Вакытның тиз узуына хәйран калырсың. Шагыйрь әйтмешли, менә без дә үсеп җиттек... Һәммәбезнең үз машинкасы бар, тик беребез дә әти юлыннан китмәде. Абыем Ис-

кәндәр тарих өлкәсен сайлады (хәзер университетта татар филологиясе һәм тарихы факультеты деканы, профессор), мин архитектура институтын тәмамладым, энебез Рәшат исә медицина институтын тәмамлады. Институттан соң мин Мәскәүдә проектлар институтында эшли башладым. Ләкин бу эш ни иҗади яктан, ни матди яктан күңелемә ятмады, канәгатьләндерми иде. Бәхетемә, бу вакытта мин Мәскәүдә гел әти белән күрешеп тордым. Ул йә язучыларның Переделкинодагы иҗат йортында ике айлап торып китә, йә төрле пленумнарга, съездларга килеп чыга. Мин Мәскәүдә булганга да шулай ешламады микән? Биредә мин бөтенләй үзгә әтине күрдем. Мәскәү язучылары арасында аның дәрәҗәсе зур, түрә халкы да аны хөрмәтли. Сүзе үтә, горур, кайчакта кибарәнә... Монда ул татар әдәбиятының, татар милләтенең күренекле вәкиле иде. Шуңа күрә ул һәрвакытта башын югары тотарга тырышкандыр да... Шул чакта минем күңелдә нидидер үзгәреш булды. Җанымның төпкелендә нәрсәдер яктырып алды сыман. Һәм мин яза башладым.

Мин ашыгып, тырышып, күп итеп яза башладым. Язып бетерү белән беренче хикәямне әтигә җибәрдем. Берничә көннән соң аңардан җавап та килеп төште: «...повестең шактый уңышлы язылган. Беренче әсәр буларак бик әйбәт! Телең бар, сюжетны сизәсең, матур чагыштыруларың, образларың бар – тырышып эшләсәң, синнән чын, заманча язучы чыгачак! Бу – иң мөһиме! Тик шуны онытма – язу эше бөтен көчне, игътибарны, гомерне таләп итә. Бу повесть синең күңел тавышың гынамы, әллә гомерлеккә атлап керүеңме? Әмма моны әйтү кыен. Минемчә, сиңа язарга кирәк. Бик нык эшләргә!»

Ләкин мине барыннан да элек театр тартаиде. Шуннан, тәвәккәлләп, мин пьесага тотындым. Пьеса язу миңа гаҗәеп ләззәт бирде, һәм мин әдәбиятның нәкъ менә шушы төре белән шөгыльләнергә карар кылдым. Драматургия – үзенчәлекле жанр, аның хикмәтле кануннары, кагыйдәләре бар. Әти – минем беренче мөгаллимем дә. Сабаклары аның бик кыска, әмма төпле, шуңа күрә аларны мин үлгәнче онытмам. Мәсәлән, бервакыт диалоглар турында сүз чыкты. Ике яшькеше очраша, берсе икенчесеннән сорый: «Исемең ничек?»

Тегесе: «Вахит!» – дип җавап бирә. Аның исеме чыннан да шулай. Әмма бу – сәхнә теле түгел.

Ул йә сораучыны алдарга, йә сүгенергә, йә сорауга сорау белән җавап бирергә тиеш. Кыскасы, һәр фразаның төбендә конфликт ятуы зарур. Әлбәттә, әти тарафыннан мондый сабаклар күп булды. Аның тагын бер киңәше нык истә калган. «Чын драматург буласың килсә, сиңа бик тиз өйләнергә кирәк, – диде ул. – Гаилә корылуга ук котылгысыз конфликт та пәйда була, ә ул драматургка һава кебек кирәк». Бу киңәшен тыңлаганда, мин аны, әлбәттә, бераз хәйләли, дип уйладым. Һәрбер ата кебек, аның мине тизрәк өйләндерәсе, оныкларын сөясе килә иде. Оныклары күп булуын теләде ул. Әмма өйләнеп яши башлагач, драматургия өлкәсендә дә аның хаклы икәненә ышандым.

Шулай итеп, мин акрын гына драматургия өлкәсенә үтеп кердем. Менә бервакыт әти миңа әйтте: «Син яшь, синең пьесаларың миңа бик үк аңлашылып бетми. Бар, син хәзер Ризван Хәмидтән өйрән». Монысы инде – мәктәпнең бүтән төрлесе иде.

Драматургия дигән катлаулы дөньяга мин шулай әтинең җиңел кулы белән кереп киттем.

Ул яһүдләргә бик хөрмәт белән карый, безне дә алардан гыйбрәт алырга чакыра иде. Яһүдләр арасында аның шактый ук дуслары һәм танышлары бар иде. Әти яһүдләрнең табигый зирәклеген, хезмәт сөючәнлеген, аеклыгын, белемгә омтылуларын хөрмәт итте. Иң мөһиме, аларның бер-берсенә ярдәм итүенә, бердәмлегенә сокланды. Әлбәттә, моның төбендә үз халкының язмышы өчен әрнү хисе ята иде. Татарның бөтен фаҗигасе аның таркаулыгында булуын ул бик яхшы аңлады. Бердәмлек идеясен бөтен халыкка җиткерә алмавына әти бик газаплана иде.

Әти турында язам, ә күңелемне бер уй бимазалый: аны сөттән ак, судан пакь итеп күрсәтергә тырышмыйммы соң мин? Билгеле, әти, һәр язучы кебек, катлаулы, каршылыклы кеше булды. Һәркемнең үзенә генә хас табигый сыйфатлар аңарда да бар иде. Еш кына ул хискә дә бирелеп китә, тотнаксыз сүзләр дә ычкындыра... Ләкин аның барлык кимчелеклә-

ре милләтебезгә, гаиләсенә, һәм, гомумән, тормышка карата булган мәхәббәте каршында хәзер бик бәләкәй булып тоела.

Мәкерле чир – шикәр чире әкрен генә аның саулыгын ашады. Тын гына сүнә баруын күзәтүе безгә коточкыч авыр булды. Ул безгә кинәттән әрнү китермәс өчен шулай махсус сүнде сыман... Дөньядан киткәндә ул, әлбәттә, безнең турыда, нәселенең киләчәге хакында уйлагандыр...

Хәзер миңа балачагымдагы коточкыч төш бүтән керми инде. Ләкин ул төшне мин йокыдагы улымның ятагы янында искә төшерәм. Кайчагында улым Муса төшендә куркып кычкыра, бимазалана, елап та җибәрә. Мин янәшәдә утырам һәм, нинди куркыныч төш күрде икән соң бу нарасый, дип уйлыйм...

*2002*

***Рәшат Гыйләҗев***

## Әтием турында

Әтинең арабыздан китүенә инде егерме елдан артык вакыт узды, ә шулай да ул төшләремә еш керә. Шунысы гаҗәп, төштә әтине гомеренең соңгы елларында мин белгән әтидән яшьрәк итеп күрәм. Аңа әйтәсе-сөйлисе сүзләрем күп булганга шулайдырмы ул? Минем аңа, үзе гомере буе хыялланганча, яхшы уллар үстерүе турында әйтәсем килә...

Әти иҗат белән яшәде. Аның өчен тормышта ике нәрсә иң мөһиме булды: гаилә һәм эш. Шушы ике хасиятне яшәү рәвеше һәм киеренке эшчәнлеге аркылы ул безгә дә сеңдерә килде. Әтинең онытылып ял иткән чагын хәтерләмим дә. Гадәттә дачада яисә «Переделкино» язучылар иҗат йортында эшләп утырганда, кыска гына ял минутларында да ул уйларыннан тулысынча арына алмый иде. Юк, аның янәшәдә булуын, мине яратуын гел тоеп тордым. Шул ук вакытта аның уйлары белән үзенең геройлары арасында булырга мөмкин икәнен дә белә идем. Һәрвакыт шулай булды.

Әти тормышка гашыйк кеше иде. Ул яшәүдән тәм табып яшәде, табигатьнең гүзәллегенә соклана белде, матур җырлар ятатты, җырларга яратты, яшьлегендә хәтта гармунда да

уйнап маташкан дип беләм. Ә бит, чын дөресен әйткәндә, үзенең җыр-музыкага сәләте-фәләне юк иде. Әмма бу гына этине җырлап җибәрүдән тыеп кала аламы соң инде?! Бу яктан без, аның балалары да, этигә охшаганбыз – колакларыбызга «аю баскан».

Хәтердән, күңел кылларын нечкәртеп, кадерле истәлекләр калкып чыга: эти, яратканымны белеп, тавык ботының берсен гел миңа бирдерергә тырыша иде. Болай да икәү генә бит инде ул тавык боты, абыйлар, бәлки, үпкәләгәннәрдер дә. Нихәл итәсең, яраткан төпчек улы бит мин этинең! Бүгенге күзлектән әлеге истәлек сәеррәк тә күренергә мөмкин, ә без үскәндә, шәһәр җирендә тавык табу – зур нәрсә иде ул! Алай да заманына күрә мул яшәгәнбез, дип уйлыйм. Эти командировкаларга, очрашуларга йөреп тора, барган җирләреннән тансык ризыклар алып кайта, зур суыткычыбыз буш тормый иде. Ә эти – киң күңелле юмарт хуҗа. Бүгенгедәй исемдә, безнең Восстание урамындагы фатирыбыздан кеше өзелми диярлек: күпсанлы туганнарыбыз, гадәттә, алар Сарман районыннан була, кунакка килә. Караватдиванга сыймаганда, урын идәнгә дә җәелә. Эти һәр кешене якты йөз белән каршылый, һәркайсына сүзе һәм гамәле белән булышырга омтыла. Без үзебез дә аның белән Сарман районына еш кайтып йөрдек. Эти бу якларны аерым бер ярату белән ярата, сәхраларда йөргәндә үзенең яшьлек елларын искә ала, озаклап һәм үтә зур ихтирам белән эти-әнисе – минем әбибабам турында сөйли иде.

Мәктәп елларымда мин «бишле»гә генә укырга тырыштым. Безнең гаиләдә башка төрле билгеләргә риза булу кабул ителмәгән иде. Эти шундый биек «планка» куйды. Ниндидер җәза бирелер дип куркудан да түгел иде бу, эти белән әнинең кайсыбызга да булса җәза биргәнен дә хәтерләмим. Үзем дә аңлап бетермәгән җаваплылык хисе – укытучылар миннән зарлана күрмәсеннәр! – барлыкка килде. Эти беркайчан да минем өй эшләрен тикшермәде, дәфтәрләремне, көндәлегемне карамады, бары тик чирекнең яхшы нәтиҗәләр белән тәмамлануын һәм төрле дипломнар алып кайтуымны көтте, һәм мин шуңа омтылдым. Хәзер, үзем ата кеше буларак, шуны гына әйтә алам: без балаларның өй эшләрен тикшерәбез,

укытучылар белән элемтә тотабыз, әмма минем әти-әнием тарафыннан безгә куелган таләпләр биеклегенә һәм аларның үтәлеше дәрәҗәсенә тиешә алмыйбыз. Безнең тәрбия ниндидер башка тәрбия иде: тавыш күтәрү юк, тикшерү-контроль юк, ә нәтиҗәсе сөендерерлек.

Тормыш-көнкүрешебез турында берничә сүз. Мин әтигә һәрвакыт ӘТИ дип эндәштем, әмма русча сөйләшкәндә, хөрмәтемне белдереп, БАТЯ дип атый идем. Безнең ӘТИ көнкүрештә, йомшак итеп әйткәндә, кулыннан эш килгән кеше түгел иде. Ул стенага кадак та какмады. Яшерен-батырын түгел, мин бу яктан «әтидән өзелгән дә төшкән» – әлегә кадәр өйдәгеләрне үз кулым белән нәрсәдер эшләп сөендергәнем юк. Әни әтине тормышның барлык эреле-ваклы мәшәкатьләреннән саклап яшәде. Әгәр шулай булмаса, язучы Аяз Гыйләҗевның күп кенә әсәрләре дөнья күрми дә калган булыр иде. Әти иҗат командировкаларында еш була, әни, шул вакытка туры китереп, өйдә ремонт оештыра. Барлык эшләр тәмамланып, әти ялт иткән фатирга кайтып керсен өчен, әзерлек эшләре ул китүгә үк башлана иде. Безнең өйдә тормыш-көнкүреш мәсьәләләрен хәл итү әни һәм әби өстендә булды, һәм бу – шулай тиеш кебек кабул ителде. Әни үзе дә, бәлки, әтисен күрми үскәнгәдер, моңа авырсынасы дип белмәде, безнең гаиләнең яшәү рәвеше итеп карады.

Без барыбыз да әтине эшеннән аерырга ярамаганын белеп үстек. Аның үзенең дә языласы әсәрләренең иң элек башында тууын, аны кәгазьгә төшерүнең җиңелрәк тоелуын кат-кат әйткәне булды. Мин әтине язу машинкасыннан башка күз алдына да китерә алмыйм. Аның эш өстәлендә гел зур, авыр язу машинкалары торды. Әти Германиядә эшләнгәннәрен ошатты, ә юлга үзе белән кечкенә язу машинкасын ала иде. Ул иртәнге якта эшләргә яратты, без аның машинкада «тук-тук» басуына уяна идек. Мин кечкенә чагымда, уенчыкка санаптыр, язу машинкаларын ваткаладым да. Үзе өчен зур проблема булса да, кат-кат төзәттерергә туры килсә дә, бу эшем өчен әтинең хәтта ачуланганын да хәтерләмим. Менә хәзер үкенечле кыенсыну кичерәм...

Китап һәм уку турында. Әти укуга мөкиббән кеше иде. Ул – мин үз гомеремдә очраткан иң күп укучы кешеләрнең

берсе. Шундый вакытлар да еш була иде: бүлмәнең бер почмагында – мин, икенче почмагында әти укып утыра. Ниндидер бер мизгел җитә – дәррәү туктап, укыганнар буенча фикерләшә башлыйбыз... Бу күренешкә бүгенге күзлектән карыйм. Мин әле дә күп укыйм, элеккечә үк түгел, әмма барыбер мин – китап укучы кеше. Укуга тартылу гадәтен миңа әти сеңдерде. Кызганыч, минем балаларым китап укымый. Әти мине аерым бер дулкынга «көйләп» калдырды, мин әле дә шул дулкында. Аның яраткан авторлары – Ремарк, Шукшин, Бунин, Сэллинджер иде. Кызык, вакытлар узу белән, мин дә нәкъ шул авторларга тартылдым – ата үрнәге шулдыр.

...Бер уй икенчесен уята. Тормышның төрле мизгелләрен искә төшерә торгач, шуны аңладым кебек: без, ирексездән, әти-әниләребез тормышын кабатлыйбыз бугай. Әти, экология турында күпкә сирәгрәк сөйләшенгән чорда да, экологиягә битараф түгел иде: сәхрага чыкса, чүп ташламас, чүп-чар һәрвакыт җыеп алыныр һәм чүп җыю урыннарына илтеп тапшырылыр. Ял иткән урыннарын чүп оясына әверелдерүчеләргә өлге иде ул. Үзем дә әти төсле бит мин. Әти агачлар утыртырга ярата иде. Мин тугыз яшьтә вакытта без өч каен утырткан идек. Шуларның икесе Восстание урамындагы йорт ишегалдында әле дә үсеп утыра. Без, әтинең өч улы, өч ир туган, агач утыртуны гадәтебез иттек.

Әти – ул үзе аерым бер дөнья. Аның турында әле тагын да язарга мөмкин булыр иде, хәзергә шушы урында тукталам.

*2023*

# Документлар

## Яшь язучы Аяз Гыйләҗев иптәшне Союзга тәкъдим[1]

Мин соңгы вакытта Аяз Гыйләҗевнең ике пьесасы белән таныштым. Берсе «Җиз кыңгырау» – театрда барганы һәм икенчесе – «Киек Каз Юлы».

Бу әсәрләр икесе дә җитди игътибарга лаек. Алар икесе дә бүгенге заман темасына, икесе дә үз кабыкларына бикләнгән кешеләрне яңа киң тормышка чыгаруга һәм кешегә карата коммунистик мөнәсәбәтләр булуга багышланган.

Дөрес, беренче пьесасы булган «Җиз кыңгырау» кимчелекләргә дә ия, анда мәчет салырга йөргән тискәре образның, ата образының мотивлашуы зәгыйфь һәм ышандырып җитми, ферма ташлаучы кызының хәле дә шулайрак. Ләкин монда гаеп авторда гына түгел, аны куючы театрда да бар. Пьеса үзе – бер эздән, сәхнәдә трактовкасы икенче эздәнрәк бара. Ягъни, пьеса сәхнәдән яхшырак яңгырарга мөмкин иде, ләкин пьеса белән уен арасында уртак тел табылмаган, димәкче булам. Шуңа да карамастан, бу әсәр тамашачының игътибарын үзенә җәлеп итте һәм яшь авторның каләм көченә өмет баглатты.

Икенче әсәре «Киек Каз Юлы» Аяз иптәшнең драматурглык таланты һәм сәләте чыннан да көчле икәнен күрсәтә. Пьесаның үзәгендә – бюрократлашкан һәм халыктан аерылган директор Бадамшин һәм аның гаиләсе. Гаепле Бадамшинны урыныннан алып, цех начальнигы итеп куялар. Ул үзен һәм халыкны аңламыйча, моны бик авыр кичерә, көнләшү һәм интрига дип карый. Ләкин кешегә коммунистик мөнәсәбәт һәм совет гуманлыгы аның бу фикерен үзгәртә,

[1] Исәнбәт Н. Яшь язучы Аяз Гыйләҗев иптәшне Союзга тәкъдим // Мәдәни җомга.– 2022.– № 22.– 15 апрель.

ул үзендә яңа ачыш ясый, һәм бу яңару аны яңадан халыкка, производствога китерә, ләкин аның иркә улы Зөфәр, хезмәт сөймәүче, эгоист буларак, кулдан ычкына, җәмгыятьтән китә.

Күренә ки, Гыйләҗев бу әсәрендә кешедә мораль тәрбия һәм бюрократлык белән көрәш темасын алган һәм теманы ачканда да коммунистик мөнәсәбәтнең нигезе булган кешегә ышану, совет гуманизмы мәсьәләсен куйган һәм, әйтер идем, ул моны уңышлы башкарган. Анда башка кызыклы персонажлар һәм ситуацияләр дә бар. Аяз иптәш бу пьесасында яңа эчтәлек бирү белән генә калмый, ул аны формасы белән дә яңача хәл иткән. Ул моңа хәтле драматургиядә булган трафарет калыплар белән бармый, бәлки үткәнне хәтерләү, кичерү төсендә кайтмалы һәм гомумән бәйсез, ирекле алымнар белән яза, кино алымнарын да җиңел файдалана, шулай булса да, төп алган темасыннан читкә тайпылмый, аны эзлекле бер юнәлештә үстерә. Гыйләҗевнең диалоглары җанлы, сәхнә теле әдәби яктан да шома, яхшы эшләнгән.

Яшь драматургның бу пьесасы сәхнәдә үз ачкычын таба алырмы, юкмы – анысы икенче мәсьәлә, ләкин әсәрнең үзен укыганнан соң, шунысын әйтеп була: Аяз Гыйләҗев, һичшиксез, үз каләм көченә һәм үз алымнарына ия булган талантлы яшь драматург икәнен күрсәтә. Ул бүгенге заман темасы белән бергә иҗат яңалыгы да алып килә. Аның бу пьесасы буенча татар һәм башкорт драматурглары киңәшмәсендә дә күп яхшы сүзләр әйтелде һәм Гыйләҗев турында «татарның яшь, яңа драматургы туды» диелде.

Драматургиябез тормыштан артка кала бара, кадрларыбыз үсми иде. Соңгы елда бер-ике талантлы яшь каләмнәребез күренә башлады. Шулар арасында Аяз Гыйләҗев инде үз каләм көчен күрсәтеп өлгерде. Мин аны Язучылар союзына әгъза итеп алырга тәкъдим итәм.

*Н. Исәнбәт*

*18.01.1961*

Редакция журнала «Дружба народов»

## Стенограмма обсуждения повести т. Аяза Гилязова «Три аршина земли» 29 августа 1963 года

Председательствует В. А. Смирнов[1].

***В. А. Смирнов.*** Товарищ Гилязов, сегодня мы хотим с вами поговорить о вашей повести в связи с тем, что она нас заинтересовала, но в таком виде мы не можем её напечатать. А в каком виде нам хотелось бы её напечатать, каждый из нас попытается по-своему рассказать.

Вадим Петрович, заведующий отделом прозы, откроет этот разговор.

***В. П. Лукашевич***[2]**.** Повесть «Три аршина земли» – это одна из современных свежих повестей, вещь талантливая и интересная по характерам. Но в то же время в ней есть, конечно, много серьёзных недостатков, в частности такие: по существу, сама повесть начинается только где-то во второй половине, потому что поначалу чрезмерно затянута экспозиция с поездом, в котором обнаруживается заболевшая женщина, как ищут кого-то из медицинского персонала.

Врач приходит, осматривает и выясняется, что состояние тяжёлое, что женщину нужно непременно направить в больницу, а муж этой женщины почему-то сопротивляется. Это давит на читателя, как крючок, на который он попадается: почему же муж протестует? Нелепое положение. Поезд останавливается даже на станции, на которой не должен останавливаться. Эту женщину и Мирвали высаживают из поезда, женщину кладут на подводу и везут за 8 км от станции. По дороге она приходит в себя. Здесь описывается, что она радуется тому, что видит поля, слышит жаворонка; радуется цветам, хлебу, который колосится. Она как будто оживает, создаётся даже впечатление, что она поправится. Но когда её привозят в больницу, она умирает.

Оказывается, что её родная деревня недалеко от этой больницы. На следующий день Мирвали берёт подводу

[1] Василий Александрович Смирнов (1905–1979) – язучы, журналист. 1960–1965 елларда «Дружба народов» журналы редакторы.

[2] Вадим Петрович Лукашевич (1905–?) – язучы.

и везёт покойницу в родную деревню. С того момента, как он идёт за телом умершей жены, и начинается повесть. Он вспоминает всю свою прошлую жизнь. Здесь выясняется почему он не хочет возвращаться в деревню, рассказывается вся их совместная жизнь.

И вот тут происходит один значительный просчёт автора. Дело в том, что по этим воспоминаниям, прерываемыми какими-то картинками, как они едут, отношение Мирвали ко всему тому, что произошло, лежит в подтексте, а не лежит на поверхности. Здесь автор немножко слишком углубил подтекст.

Мирвали – сын кулака. Он полюбил девушку-беднячку. Отец был против, но Мирвали женился на ней. Отец выгнал их, и они жили у одной старушки. Работали и были счастливы. Затем отец умер, и Мирвали стал наследником его имущества. Приходит время коллективизации. Ему говорят: мы тебя знаем, отец тебя выгнал; раскулачивать тебя мы не будем, но ты отдай имущество в колхоз. Но здесь в нём заговорило крестьянское чувство: это моё. И он, несмотря на то, что его умоляет горячо любимая жена: ведь у нас ничего не было, когда мы жили у этой старухи, но мы работали и были счастливы,– на что тебе это имущество,– Мирвали отравляет зерно, губит скот и ночью из деревни уходит. Это преступление, которое не даёт ему вернуться в деревню, хотя жена всё время об этом напоминает. Она тоскует по деревне, и он знает, что она тоскует.

Что остаётся в подтексте? Происходит ведь то, что Мирвали болеет тем, что он совершил ошибку. Ему хотелось бы вернуться, он раскаивается давно, но вернуться он не может. Нужно, чтобы этот подтекст вышел ближе к поверхности, чтобы это можно было ощутить.

***В. А. Смирнов.*** Чтобы всё последующее было понятно, но чтобы это не было сразу сказано, а чтобы были какие-то поступки, какие-то слова, мысли, чтобы это не сразу шло.

***В. П. Лукашевич.*** Это можно сделать с помощью редакции и переводчика. Автор показал большое понимание и психологии, и такта, и я думаю, что он с этим справится.

Когда Мирвали привёз в деревню мёртвую жену (её очень любили там), её хоронят всем селом. Когда её похоронили, он понял, что единственным близким человеком для него была жена. Её он похоронил, а вся деревня (там это очень ясно проступает) относится к нему очень холодно, они ему не простили. Реплика Мирвали: «Этот человек хотя бы зятем меня назвал». Он чувствует, что ему остаётся уходить. В последний момент приходят к нему и говорят: «Что тебе уходить? Оставайся уж в этом селе».

Если вы покажете, что он давно понял и мучается тем, что он совершил когда-то, что он раскаялся (жена ему правильно говорила, что ты не гордись, приди к народу и покайся) – может быть, это, или ещё какой-нибудь вариант, может быть, но что-то надо внести такое, чтобы эти люди не просто отнеслись к нему со снисходительным великодушием, но чтобы был какой-то поступок с его стороны, который мог бы это подтвердить.

***Б. В. Яковлев*[1].** Я мало что могу добавить к тому, что сказал Вадим Петрович. Я разделяю оценку повести и думаю, что в повести есть самое главное: есть характеры, есть много глубоко понятой психологии человека и нет того, что следовало бы назвать искуплением. Если после ухода из села ничто не остаётся в его памяти, кроме ощущения чужбины (это не самое удачное слово), если ничто на протяжении 30 лет его жизни не привело его к мужественному героическому решению, о котором идёт речь в конце, то это решение будет казаться надуманным, неоправданным и незакономерным.

Думается мне, что Мирвали не должен быть такой поразительной скотиной, как возникает в разных местах повести, как написал её автор. Я не хочу просить об изменении характера, то это скотство должно быть ослаблено.

И в самой развязке повести речь должна идти не о толстовском решении всепрощения, когда родичи предлагают ему остаться, говорят, что тебе на старости лет некуда идти, оставайся с нами,– поскольку он юридически и нравственно совершал преступление, то это преступление должно быть

[1] Борис Владимирович Яковлев (1913–1994) – «Дружба народов» журналы хезмәткәре.

искуплено. Здесь должна быть изменена мотивировка развязки: герой должен просить односельчан о прощении, а не сами односельчане должны просить его остаться. Если этот акцент будет изменён, самое главное в повести будет сделано.

Я не могу согласиться со сценой, где герой тайно от жены посещает деревню. «Всё по-старому». Нет, не по-старому. «Чужбина» – это немыслимое слово, оно не подходит, когда речь идёт о жизни героя вне села, это немыслимый для советской страны акцент. Но это может быть устранено в процессе редактирования.

Концовка, развязка – это символический вывод из всего происходящего, это самое главное. Если этот вывод автор найдёт и оценит то, что произошло с этим человеком, как со многими тысячами и сотнями тысяч людей за десятилетия, тогда повесть примет тот вид, какой должен быть.

Вне этого это будет повесть о нераскаянном. Он кающийся, но не раскаянный. Это решается развязкой не только в смысле композиционном, но и психологическом. Вадим Петрович советует постепенно подвести героя к такому решению. Вещь от этого только выиграет.

Более подробно я сейчас выступить не могу, так как уезжаю, и у меня много дел перед отъездом.

***А. А. Салахян***[1]**.** Я читал эту повесть до того, как уезжал в отпуск. Когда я прочитал эту небольшую повесть, я почувствовал, что автор несомненно талантливый человек, который умеет находить в жизни и ситуации интересные, своеобразные и острые, и подходить к ним оригинально,– по крайней мере, стремится к этому.

Общий вывод, который я сделал для себя, такой, что эта вещь стоит того, чтобы работать над ней и приобрести для журнала. Это вещь стоящая, потому что чувствуется интересный хороший автор.

Как об этом сказал уже Вадим Петрович, и мне кажется, что слишком затянуто начало вещи. Иногда создаётся впечатление, когда обращаешься к этому зачину, что автор

[1] Акоп Ншанович Салахян (1922–1969) – әдәбият белгече, тәнкыйтьче, «Дружба народов» журналында баш редактор урынбасары.

искусственно как-то тянет, растягивает вещь, и это во вред автору. Это не только создаёт впечатление искусственности, но и отвлекает внимание читателя. От главного, основного он слишком удаляет внимание читателя. Писать о главном и основном нужно начать писать как-то раньше. Можно посоветовать автору в первую очередь подумать о том, чтобы это начало, этот зачин сделать максимально экономным, не растягивать его. Это начинает раздражать, нервировать читателя. Начинаешь думать, что автору нечего сказать, раз он так затягивает.

И второе – судьба этого героя, который в общем прожил трагическую по своему жизнь и сейчас возвращается к какой-то настоящей жизни. Где-то мимо его всё произошло, хотя я не думаю, что его жизнь была жизнью паразита, который стоял в стороне, но вещь выиграла бы, если бы автор сумел показать, что на протяжении того времени, когда Мирвали жил вдалеке, не только жена его всё время думала об этом родном селе, но что этой мечтой возвратиться туда был заражён и захвачен он сам. Тогда вся проблема вещи выльется в этом. Дело не в том, что старушка-жена его тоскует по родным местам, хочет увидеть эти места и умереть там, но и в нём самом, несмотря на противоречивость его натуры, есть этот голос, зовущий его к настоящей большой жизни, к признанию большой правды, которая там есть. Пускай это не будет подано в качестве главного идейного мотива произведения, но хотя бы как один из главных мотивов, который определит в этом смысле жизнь этого человека.

В конце концов, как мы будем с этим человеком обходиться? Достоин ли он того, чтобы остаться там, или в общем-то жизнь прошла мимо? «Иду родной стороной, как проходит косой дождь». Это рассказ о том, что он прошёл косой струёй или это рассказ о том, что в силу большой правды людей, которые были там, он признал великую правду их? Этот акцент должен быть определён, вещь от этого выиграет.

Может быть, где-то более экономно дать начало вещи, чтобы потом более свободно, щедро и более пространно поговорить об этом глубинном процессе, показать его пересмотр всей своей жизни, переоценку всего, что он делал. Хорошо,

что он идёт как оппонент своей жены, жена его тянет туда, но пусть это будет на поверхности... отношений между ним и женой, которые вы описываете. Пусть я почувствую, что в действительности он тоже от этого болеет и страдает. Такой финал даст право на жизнь и существование не просто героя, но героя произведения, не просто персонажа, но героя произведения. Если такой акцент будет уточнён, тогда вещь приобретёт смысл. В этой повести тогда будет сказано, как трудно таким людям жить, и как у этих людей, в общем, были всякие перспективы, связанные с жизнью и делами их людей. Если не будет этого акцента, создаётся впечатление, что это кающийся дворянин. Я не думаю, что это было проблемой вещи.

***В. А. Чалмаев***[1]**.** Я читал повесть месяц назад и конкретного обаяния текста я не сохранил, но вы правильно очертили главный облик повести. Автор, может быть, не вполне продумал, какая ответственность перед писателем: поставить в центре произведения отрицательного героя и через него высказать своё художественную идею. У многих этого не получалось. Недавно мы читали рассказ А. Блока «Измена». Там предатель слабее выглядит, чем герой. Вот дезертир, сбежавший с фронта и просидевший войну в землянке в лесу. Здесь роль писателя ответственная, чтобы не погрешить против истины, не заслонить его переживаниями действительного героя современности. Нужна ли эта фигура, чтобы этой фигуре посвятить всё повествование? Автору нужно ещё раз подумать, во имя чего, во имя какой идеи вы берётесь описывать переживания этого героя.

***В. А. Смирнов.*** Почему отрицательного героя? В этом и смысл, что он не отрицательный, что этот человек из класса, нам враждебного, приходит к нам. А чем вы объясните, что у нас уже нет классов, что наше государство стало государством с двумя дружественными классами? Где же остальные? Некоторые живут. Что они – враги? Нет, они приняли советскую власть. Это главная тема этой вещи, что эти люди покорены нашим временем и нашим обществом и идут в это общество с открытой душой.

---

[1] Виктор Андреевич Чалмаев (1932) – әдәбият белгече, тәнкыйтьче.

***В. А. Чалмаев.*** Я не назвал его положительным или отрицательным (может быть, я перегнул), но это герой-одиночка, живущий в пятидесятые или шестидесятые годы очень далеко от того уровня, на котором живёт большинство народа. И такой человек поставлен в центре внимания. Я говорю об ответственности, которую автор должен сознавать.

Тут правильно Василий Александрович сказал, что такие люди, которые покорены правдой жизни, вернулись к тому, с чем они вначале не примирились. Мне показалось, что автор мог бы ещё больше убедить в своей идее – идее покорения этого героя правдой народа, правдой жизни, если бы самому народу было уделено больше места. Так бледно даны остальные лица, что они только подыгрывают этому герою. Пусть он остаётся главным, пусть психологическая жизнь его остаётся в центре внимания, но нужно найти где-то этих людей. Например, проявились новые черты людей в поезде. Весь мир как-то от него улетел. В его поле зрения почти не попадает людей живых, здоровых, живущих иными мыслями и настроениями; очень мало попадает типичных обстоятельств нашей современной жизни.

Привлекательная для характера героя черта, когда он запускает руку в зерно – ему приятен запах зерна; или другая черта, когда он запрягал коня – как он с такой сноровкой, легко это сделал. Эти две черты с зерном и конём показывают, что в нём есть здоровое труженическое начало. Но почему другой человек не обладает такими чертами, почему это тонкое чувство стало присуще только ему? Он только выгодно так показан с хорошей своей стороны. Может быть, на мельнице он мог бы увидеть других людей.

Мог бы земляка встретить.

***В. А. Смирнов.*** Это правильно.

***В. А. Чалмаев.*** Здесь ведь целая эпоха и в его поле зрения многое попадало бы и вызывало бы его отклик. Он психологически бывает часто безмолвным.

Правильно, что затянуто это вступление. Герой там не живёт, он замкнулся.

***В. Н. Лукашевич.*** Там есть одна черта: внимание людей советских.

***В. А. Чалмаев.*** Но он какой-то немой, я не ощущаю его потока сознания. Может быть, вы хотите показать, что только смерть жены прорвала эту плотину?

***В. А. Смирнов.*** Это правильно, смерть жены была последней каплей.

***В. А. Чалмаев.*** В нём что-то уже дрожало, а тут – такой момент.

***В. А. Смирнов.*** В поезде картину нужно сократить, а его сознание должно быть настороже, он должен волноваться, чтобы можно было понять и так и так, и чтобы непонятно было, что происходит. Всё-таки, крючок сюжетца здесь должен быть.

***В. А. Чалмаев.*** Нужно, чтобы он, с одной стороны, сопротивлялся, а с другой стороны, волнение его нарастало. Его психологическая жизнь начинается, когда он едет с подводой.

Нужно усилить воздействие на него жизни, и чтобы в его поле зрения попали хорошие люди, от которых он прятался бы или, подражая им, понемножку преображался бы. И психологическую жизнь его нужно расширить: не только после смерти жены, но и подготовка прорыва этой плотины до этого.

Что касается взаимоотношений его с остальными крестьянами, то я думаю, что не в том дело, что он должен у них просить прощения. Высота жизни в том и состоит, что не нуждается в его запоздалой мольбе, чтобы он просил разрешения остаться и т.д. Но так написать: ну, уж, оставайся здесь, сам ты виноват, что не так прожил жизнь.

***В. А. Смирнов.*** Он сам должен что-то сделать. Представьте себе положение колхозников. Многие из них знают, что он совершил. Он приехал. Он должен каким-то жестом, словами, состоянием показать, чем он мучается. А то получается, что его приглашают остаться.

***В. А. Чалмаев.*** Нужно, чтобы люди сказали ему, что ты прожил такую жизнь и оставайся уж у нас, живи у нас.

***В. А. Смирнов.*** Если мы ведём его к тому, что он идёт к этому решению, извольте это решение сказать. Нужно, чтобы этот герой выразил свою главную мысль поведением,

своими поступками – не знаю чем, но чтобы читателю было понятно.

Конец очень слабый, он слабо написан, недостойно этой вещи. Конец надо развить.

***В. А. Чалмаев.*** По поводу жены. Она женщина с сознанием ещё не развитым, она покорна судьбе, но если она сумела убедить его ехать, в ней недостаёт психологической правды. Она однотонна. Автор немножко аскетически подавленно ведёт их отношения. У меня такое чувство, что она сильного характера, вообще, человек.

***Е. Л. Усыскина***[1]***.*** И сильного, и мягкого в одно и то же время.

***В. А. Чалмаев.*** Но автор подавил их, в аскетической форме подал их. У ней тоска по родине, и она заставила его поехать. Он больше всего изолирован, а жена более открыто живёт. Но она всё-таки немножко немая.

***В. А. Смирнов.*** Да, она только просится ехать.

***В. А. Чалмаев.*** Она – беднячка.

***В. А. Смирнов.*** Отсюда надо исходить.

***В. А. Чалмаев.*** Через неё в первую очередь заносятся к нему новые начала жизни, и это должно остро сказаться.

Вещь талантливая. Это психологическая драма, драма индивидуального сознания собственничества. Острота этой драмы приглушена сейчас, но это важно показать, что человек губит в себе лучшие человеческие качества. Эта повесть этим гуманизмом сильна.

Относительно растянутого начала правильно было сказано. Это влияет и на художественность вещи.

***Е. Л. Усыскина.*** Сейчас создаётся ощущение, что Мирвали хочет здесь остаться. Он стар, немощен, одинок и некуда ему идти. От этой интонации нельзя отказаться. Он прожил 30 лет в Сибири, но всё-таки в Советском Союзе, не за границей. Что-то у него накопилось подсознательно, и в конце должно быть не только ощущение подавленности, но и мысль о том, что здесь делается дело, которому он сочувствует. Она вышла с красным полотенцем и он заставил

---

[1] Евгения Львовна Усыскина – «Дружба народов» журналы хезмәткәре.

убрать – это была соль на рану. Нужна интонация, что его проступок должен всё больше и больше его угнетать – не потому, что он боится суда, но он чувствует своё положение неприкаянности, и тогда к концу это будет сведено в общий поток, и всё будет ясно.

Конец, конечно, нужно изменить. Дело не в том, кто кого прощает. Здесь должен произойти или разговор, или размышление, или внутренний монолог, но чтобы было сказано перед концом, что он останется здесь. Он всем своим существом пришёл к этому, а не потому, что он стар. Этой общественной позиции здесь немножко не хватает. И, конечно, нужно сократить начало.

И в середине вещи, после этого начала, начинаются воспоминания, как они живут у этой старухи. И потом вдруг они оказываются на Востоке, и он исключительно груб и равнодушен к жене. Всё это глубоко спрятано и нам непонятно. Но там, где рассказывается, что умер отец и он не получает наследства, тогда начинает мелькать более человеческое отношение к жене, вы начинаете чувствовать подтекст. Зачем вы это придумали? Этого не нужно. Не нужно этого второго круга.

Не нужно сперва рассказывать, как он жил, потом – почему он уехал из деревни, и опять рассказывать, как он жил. Если бы вы это свели в одну общую картину и что-то ещё от себя написали, было бы лучше.

Он думает: «жаль, что я не пошёл на войну, тогда иначе сложились бы отношения с женой». Но где бы они ни жили, он не задумывается над тем, что идёт война. Рядом люди работали круглосуточно, вся атмосфера жизни была другой. Постепенное накопление в сознании должно было происходить. Если бы у вас не было ограниченности этих двух кругов, вам это помогло бы. Это конструктивно не совсем правильно.

Это всё, что я хотела сказать. Обязательно сократить начало, не делать Мирвали таким зверем и изменить конец.

***В. А. Смирнов.*** Вообще, всю вещь нужно уплотнить. Чем она будет плотнее, тем лучше.

Когда он везёт труп жены в гробу, это место нужно сократить, нельзя так долго об этом говорить. Нужно, чтобы это было плотнее.

Почему мы заинтересовались вашей повестью? Вещь заинтересовала необычной своей психологией. У нас есть обломки старого мира: как они чувствуют себя? И вы показываете путь возвращения этого человека.

Или в этом, или в 9-м номере журнала мы печатаем вещь казахского писателя, повествующую, как целая семья во время коллективизации перешла границу и жила в Китае и там счастливой жизни не обрела. Умирают мать, отец и брат, остаётся сын, которому отец завещает вернуться на родину. И он возвращается – и вот ощущение этой новой жизни. Хороший рассказ в форме небольшой исповеди.

То, что вы написали, это типично. Это тоже какая-то категория населения нашего общества, которая есть, которая или была нам классово враждебна, или волей обстоятельств была оттолкнута от нас жизнью, но и она возвращается к нам и идёт с нами вместе. С этой точки зрения ваш рассказ очень ценен.

В последнее время из Татарии маловато поступало произведений. Мало от вас произведений было у нас, и мы ухватились за вашу повесть обеими руками. Хочется напечатать её в журнале, но в таком виде, как она есть, мы её не напечатаем. Речь идёт не о том, чтобы два-три слова добавить или что-то выкинуть, а мы говорим о серьёзной доработке вещи. То, что мы советуем, сделает вещь более художественной и более правильной. Если вы на это пойдёте и доработаете её, мы напечатаем её в первых номерах будущего года.

Я согласен со всеми товарищами, которые высказывались. Это единые наши замечания, спора тут нет. Все товарищи в один голос говорят и, значит, правда лежит где-то тут, и говорим мы об этом с горячим желанием помочь вам. А как это сделать, вы лучше нас это сделаете. Вы – творец этой повести, и вам это понятно. Найдите эти ходы, которые показали бы его сложную противоречивую психологию. Он сначала порвал с отцом, пошёл как бы вместе с нашим обществом, а потом, когда дело коснулось наследства, струны собствен-

ника в нём заиграли и он совершает такие вещи, как что-то ломает, убивает скот и т.д. и даже собирается что-то сжечь.

***В. Н. Лукашевич.*** Когда он едет туда, ему кажется это.

***В. А. Смирнов.*** Это лишнее, когда он едет туда, не надо доводить его до исступления.

Он должен чувствовать какую-то симпатию к этому новому, что он должен пойти с ним, но этот сдвиг трудно будет объяснить два раза. Если бы он не женился на этой беднячке, не пошёл против отца, тогда вы могли бы иметь несколько перспектив: он возвращается обратно, снова уходит и т.д. А тут достаточно: он влюбился в девушку-беднячку и уходит, и этого достаточно. А потом тонкие детали приводят его к тому сознанию, что он должен вернуться, что тот мир прав, а не он.

Вы этот подтекст поднимите, кое-что дайте попрямее. Нужно усилить образ и его жены, её роль и её влияние и посильнее сделать конец. Я сократил бы поход с гробом и перенёс бы какие-то воспоминания на ту часть, когда жену похоронили. Это очень тяжело; он что-то вспоминает. Часть его воспоминаний перенесите и усильте ту сцену, когда он уже похоронил жену.

Если вы к нашим советам серьёзно отнесётесь, то я убеждён, что повесть эта получится, и я сказал бы, что она будет приметным явлением нашей литературы, а татарской тем более. Она будет верно работать на нас.

***Гизатуллин***[1] (переводчик). Хорошее впечатление получается. Видно, что товарищи внимательно читали и оценили повесть правильно.

Это первая вещь Гилязова, которую я перевожу. Хотелось бы кое-какие вещи уточнить сразу.

Основная концепция героя. Я этого никогда не принимал так, что произошёл взрыв только его собственнических мыслей. Коллективизация идёт в стране, вокруг довольно резко и круто раскулачивают, ссылают и т.д. его ударило что? Что его судьбу решали без него. Склад характера у него такой. И то, что он с отцом порвал, с этим связано.

[1] Искәндәр Галиәскәр улы Гыйзәтуллин (1922–1976).

А как он жил в Сибири? Советская действительность представлена как? Жить можно. Он работал. Нигде не видно, чтобы его наказывали или что. И преступление, которое он совершил, очень давнее. Вы говорите о прощении. Там не прощают. Прошло 30 лет. Преступление крупное он совершил, но сколько безвинного народа за это время пострадало и вместе со всеми и Мирвали можно было бы прощать. Но его не прощают. На кладбище никто его ни о чём не спрашивает.

Последнее замечание мне понравилось, что жизнь на такую высоту поднялась, что никаких счетов сводить не надо.

А психология Мирвали? Повесть произвела впечатление талантливой из-за чего? Из-за характера Мирвали. Это круто замешанный характер – вот что покоряет в повести. Если это ввести, что люди где-то есть, с которыми он встречается, от этого вещь потеряла бы.

***В. А. Смирнов.*** Это ваше главное условие. Если вы оставите его, как он есть, о чём разговаривать?

***А. А. Салахян.*** Тогда вырастет серьёзная большая проблема.

***В. А. Смирнов.*** Рассказ должен утверждать, что не из-за его характера он возвращается, а что бытие определяло его сознание. Показать нужно, что работает на него. Это основное наше предложение. Тогда вещь получается.

А что он возвращается на родную землю умирать – это неверно, мало этого сказать.

***А. М. Гилязов.*** Прежде всего позвольте поблагодарить товарищей, которые так близко к сердцу приняли мою повесть. Я даже не ожидал такого отношения, мы привыкли к суровому отношению до некоторой степени.

***В. А. Смирнов.*** Здесь, у нас?

***А. М. Гилязов.*** Нет, вообще. У вас я первый раз. У меня писательская биография небольшая.

Когда я получил письмо от Вадима Петровича, я сразу стал думать над повестью. Здесь было сказано то же самое, что изложено в этом письме, и я сразу должен сказать, что даже до этих мыслей я готов был согласиться, что экспози-

цию нужно сократить, изменить темпы, сжать. Это в первой части, это безусловно.

Но я не очень согласен, когда мой товарищ сказал, что все быстро его прощают. Я думаю, что приняли его сурово.

***В. А. Смирнов.*** Холодно, настороженно.

***А. М. Гилязов.*** Тридцать лет никто не даёт имя Мирвали ребёнку, его судьбой никто не интересуется. Его дом развалился, на усадьбе растёт сорняк. Даже обходят этот дом. Никто не называет его ни товарищем, никак. Всё изменилось, всё по-новому. А он противостоит обществу один. Мне казалось, что не так уж быстро его восстановили.

В первом варианте его не прощали, он должен был уезжать. В правлении колхоза (там его товарищ близкий, в молодости почти друг) ему отказали. Он приходит и видит запряжённую лошадь. Он понял всё и уехал.

Когда опубликовали повесть на татарском языке, мне сказали, что слишком это жестоко, что наш национальный характер не так жесток.

***В. А. Смирнов.*** И вы спешно дописывали, и это чувствуется. Последняя часть слабовато сделана.

***А. М. Гилязов.*** Вы правильно говорите. Я не хотел писать большую повесть, я хотел это сделать тонкими штрихами, отдельными деталями. Один из товарищей сказал, что мне следовало бы односельчан показать шире. Я так хотел, такая мысль была у меня, но это получалось слащаво и литературщиной попахивало. Если я начну описывать деревню, я хотел бы это сделать очень мелкими деталями. Он видит, что всё изменилось. Я не мог внести отдельных людей, ведь всё это происходит в очень короткое время. В татарской деревне в этот же день хоронят труп, на ночь не оставляют. Вечером она умерла, ночью он её вёз и в этот же день хоронит, на ночь оставить было невозможно.

***В. А. Смирнов.*** И общественных деятелей так хоронят?

***А. М. Гилязов.*** Сегодня утром умер, вечером уже хоронят по нашим законам. Он похоронил, посидел на кладбище. Потом сразу идёт к родственникам и видит, что никто не простил его.– «Иди чай пить». А ему нужно всё село. Он

ищет у представителей закона. Раскаяние. Этот текст нужно раскрыть.

Как он поступил на мельнице, это показывает, что он действительно крестьянин душой и телом. Я не хотел изобразить его зверем и изобразить его кулаком. Если бы он был только кулак, он не был бы близок мне как человек.

Но в концовке нужно что-то подчеркнуть особенно. Раз в концовке должно что-то подчеркнуть, я должен подготовить это немножко раньше. Подтекст надо раскрыть. Это надо будет сделать.

Я внимательно слушал. Но сразу на все предложения трудно ответить, нужно подумать.

Я думаю, что с вашей помощью мы дело доведём до кондиции. Я постараюсь ваши требования удовлетворить.

***В. П. Лукашевич.*** То, о чём мы говорили, уже заложено в вашей вещи.

***В. А. Смирнов.*** На этом мы первый разговор окончим. Будем считать, что автор с нами согласился, дал согласие на доработку.

Теперь надо установить вам какой-то срок. Какой вы могли бы взять срок, через который вы могли бы представить рукопись? Месяца вам будет достаточно?

***А. М. Гилязов.*** Вполне.

***В. А. Смирнов.*** Если считать, что сегодня 1 сентября, вы работу сделаете к 1 октября. Рукопись вы представляете нам уже в переводе. А вам сколько времени нужно для перевода?

***Гизатуллин.*** В зависимости от объёма переработки и как вы потребуете. К ноябрю я, конечно, всё сделаю.

***А. М. Гилязов.*** Даже после переработки может быть редакторская правка. Два месяца у вас будет: сентябрь – октябрь.

***В. А. Смирнов.*** В ноябре вы представляете рукопись, мы читаем, заключаем договор. Хотите и с вами заключим договор в ноябре, когда получим.

***А. М. Гилязов.*** То, что вы сказали, было сказано очень разумно.

***В. А. Смирнов.*** Вещь будет не только напечатана, но и выйдет книгой в Москве, и мы поможем книгу издать.

А для связи, переписки, и т.д. шефом-редактором будет Евгения Львовна и, конечно, Вадим Петрович, как высшее начальство. Договорились.

## Премии журнала «Дружба народов»

На днях состоялось расширенное заседание редакционной коллегии журнала «Дружба народов» совместно с московским активом общественного редакционного совета. С отчётом о проделанной работе выступил главный редактор журнала В. Смирнов. Его заместитель А. Салахян рассказал о планах редакции на первое полугодие 1965 года.

В обсуждении плана приняли участие: М. Ибрагимов (Азербайджан), Р. Сирге (Эстония), С. Агабабян (Армения), А. Прокофьев (Ленинград), Я. Смеляков (Москва), Л. Новиченко (Украина), В. Мачавариани (Грузия), И. Шамякин (Белоруссия), М. Каратаев (Казахстан) и другие.

Редакционная коллегия присудила литературные премии журнала «Дружба народов» за материалы, опубликованные в журнале в 1964 году, следующим авторам.

Первые премии: С. Крутилину за повесть «Липяги», Д. Кугультинову за поэму «Живая вода» и цикл стихотворений.

Вторые премии: А. Межирову за перевод поэмы Ю. Марцинкявичюса «Кровь и пепел», А. Штейнбергу за перевод стихотворений поэтов Татарии и Чувашии – «Волжская тетрадь», А. Гилязову за повесть «Три аршина земли», Р. Хакимову за очерк «Сердце моё, Башкирия!».

Третьи премии: В. Солоухину за очерки «Славянская тетрадь», Г. Маргвелашвили за статью «Поэзия молодости и весны», А. Сизоненко за рассказы, А. Овчаренко за статью «Большой, настоящий человек мира сего...», Р. Панальнишкису за статью «Поэзия – личность время».

*1964*

## Проза һәм балалар әдәбияты секцияләренең берләштерелгән утырышы БЕРКЕТМӘСЕ

9 март 1976 ел

Секретарь: Кояш Тимбикова

*Утырышта катнаштылар*: ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре Роза Баһаветдинова, КПСС өлкә комитеты инструкторы Илгиз Хәйруллин, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов, идарәнең җаваплы секретаре Равил Фәйзуллин, идарәнең оештыру секретаре Мөсәгыйть Хәбибуллин, Татарстан китап нәшрияты директоры Гарәф Шәрәфетдинов, нәшриятның баш редакторы Марс Шабаев, язучылардан Фатих Хөсни, Гомәр Бәширов, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Әхсән Баян, Шамил Рәкыйпов, Мөхәммәт Мәһдиев, Хәсән Сарьян, Вакыйф Нуруллин, Җәвад Тәрҗеманов, Әхәт Гаффаров, Хәкимҗан Халиков, Гарәфи Хәсәнов, Мәҗит Рафиков, Габдулла Шәрәфетдинов, Фаил Шәфигуллин, Галимҗан Латыйп, Таһир Нурмөхәммәтов, Роберт Батуллин, Мөдәррис Әгъләмов, Фәрваз Миңнуллин, Гөлшат Зәйнашева, Фәнил Мансуров, Кояш Тимбикова, Мәдинә Маликова, Адлер Тимергалин, Рөстәм Мингалимов, Барлас Камалов, Мәгъсүм Насыйбуллин, Марзия Фәйзуллина, Роза Хафизова, Мәгъсүм Хуҗин, Резедә Вәлиева, Зиннур Насыйбуллин, Фәннүр Сафин, Ренат Мөхәммәдиев, Шаһидә Максудова һ.б. Барысы 70 ләп кеше.

### Көн тәртибе:

Аяз Гыйләҗевнең «Күзгә-күз» исемле повестен тикшерү.

ТЫҢЛАНДЫ.

1. Венера Ихсанова («Яшь ленинчы» газетасы редакторы):

«Яшь ленинчы» пионерлар газетасы булса да, октябрятлар һәм пионерлар өчен әдәби материалларны күп бирү белән бергә, 8–10 нчы класс укучыларына кирәкле әйберләр бастыра. Соңгы вакытта алып барган тикшерүләргә караганда, 7–9 нчы класс укучыларының яртысы диярлек газетабызны укып баралар. Алар өчен «Сиңа әйтер сүзем бар» рубрикасы, шигырьләр, публицистик мәкаләләр бирелә. Ш. Рәкый-

пов, В. Нуруллин, А. Гыйләҗев, Ә. Баянов, Р. Төхфәтуллин, Г. Ахунов һ.б. язучыларның әсәрләре «Яшь ленинчы» да басыла һәм яшүсмерләргә адреслана.

«Социалистик Татарстан»да мәкалә басылып чыккач, редколлегиянең киңәйтелгән утырышында сөйләштек, бүлек каршындагы редколлегияне яңарттык, хикәяләргә ябык конкурс игълан иттек.

Редколлегия ип. Тәрҗемановның репликасын нигезсез дип бәяли.

1. Пионер газетасына «аракы» сүзе керергә тиеш түгел, ди ип. Тәрҗеманов. Повестьны укыгач та мин өлкән язучылар белән киңәштем, һәм аларның уңай фикерен алгач, әсәрне газетага басарга булдык. Мәскәүдә пионер һәм комсомол газетасы редакторлары семинарында КПСС Үзәк Комитетының матбугат бүлеге мөдире иптәш И. А. Зубков безнең республикада эчүчелекнең нык тамыр җәйгәнлеген сөйләде: «В Татарии на 24 процента выросло употребление спиртного. В 1974 г. свыше 4-х тысяч комсомольцев было привлечено к административным взысканиям. Каждый десятый мальчик и девочка побыли в вытрезвителе. Комсомольские газеты Татарии в этой ситуации взяли странную позицию...» – диде ул. Бу сүзләрдән пионер газетасы да эчкечелеккә, хулиганлыкка каршы көрәштә өлеш кертергә тиешлеге аңлашыла. ВЛКСМ Үзәк Комитетының матбугат, радио һәм телевидение секторы мөдире А. А. Полищук та шушы фикерне раслады. Димәк, репликадагы тәнкыйть ип. Тәрҗемановның бүгенге балалар тормышыннан ерак торуын, балалар әдәбиятына бүген куелган таләпләрне белеп бетермәвен күрсәтә. Әсәрнең идея-эстетик эчтәлеген ачмыйча, җөмләләрне аннан-моннан җыеп кына реплика язу «Яшь ленинчы» газетасын укучылар күзеннән төшерү өчен эшләнелгән кебек. Моның шулай икәне ип. Тәрҗемановның язучыларның ачык партия җыелышында сөйләгән дәлилсез чыгышы да күрсәтте: «Яшь ленинчы»ның съездга багышлап чыгарылган санында Җәүдәт Дәрзамановның «Ышана бар дөнья» дигән шигыре басылган иде. Ип. Тәрҗеманов бу шигырьне «идеясез, партиягә каршы шигырь» дип атады һәм газетаның идея-политик платформасын үзенчә бәяләргә тырышты.

«Күзгә-күз» повесте, нигездә, уңышлы әсәр, һәр әсәрдә диярлек булырга мөмкин булган стиль кытыршылыклары, җөмлә чатаклыклары монда да калган. Редакция репликадагы тәнкыйтьнең шуларга кагылган өлешен дөрес дип таба.

Укучыларыбызның бәясенә килсәк, алар әсәрне җылы кабул иттеләр. Повесть турында язылган хатлар менә шул турыда сөйли: «Күзгә-күз» повесте безгә бик ошады. Әсәрдәге яшүсмерләргә дөрес юл күрсәтүче Г. Кәрамов, тайгак юлдан дөреслеккә юл алырга үзендә көч тапкан Җәүдәтләр аеруча ошады. Дөрес юл күрсәтүче мондый әсәрегез өчен рәхмәт, Аяз абый!» (Хәйруллина Ләйсән, Зәй районы, Бигеш мәктәбе, 4 Б кл.)

«Моннан соң да «Яшь ленинчы»да «Күзгә-күз» кебек яхшы әсәрләр басылып чыгуын телим». (Хаҗиева Гөлүсә, Актаныш районы, Сәфәр мәктәбе, 8 кл.)

«Нинди матур повесть, ул тормышның эченә кереп язылган» (Хәлиуллина Резедә, Зеленодольск районы, Олы Ачасыр мәктәбе, 9 кл.)

Бу хатлар укучыларыбызның әсәрне дөрес аңлавын, дөрес бәя бирүен күрсәтә.

2. Гарәфи Хәсәнов:

Аяз Гыйләҗевнең «Күзгә-күз» повесте турында мин узган партия җыелышында ук сөйләргә теләгән идем. Көн темасына язылган әсәре өчен язучыны нигә кыйныйбыз соң әле без? «Яшь ленинчы» да «аракы» сүзен атамау белән генә берәр нәрсәгә ирешәбезме соң бүгенге көндә? Юк бит, иптәшләр. Бүген бит сер түгел, кайбер укучыларның әтисе, хәтта әнисе дә эчә. Алай гына да түгел, өлкән яшьтәге мәктәп балалары үзләре дә эчә бит бүген. Хәтерлисезме, урыс язучысы Крапивинның «Пионерская правда» газетасында шундый ук темага бер әсәре басылган иде. Крапивинга бу әсәре өчен Комсомол премиясе бирделәр. Аяз Гыйләҗевне бу юлы да кирәкмәгәнгә «кыйный» башламадыкмы икән? Художник бит ул.

3. Мөдәррис Әгъләмов:

«Яшь ленинчы» менә ничә еллар инде балаларны гына түгел, яшүсмерләрне дә уңышлы тәрбияләп килә. Газетаның бу зур хезмәтенә баш иям мин. Аяз Гыйләҗев исә соңгы ун

ел эчендә яшүсмерләр өчен нинди матур әсәрләр бирде. Аяз хәтле язган кеше бармы безнең арада?! Язучының «Кызлар хатлары»н алып карагыз. Аязның «Яшь ленинчы»да басылган «Күзгә-күз» повесте яшүсмерләрнең язмышы турында кайгыртып язылган. Без бүген Аяз Гыйләҗевнең «Күзгә-күз» повестеның балаларгамы яки түгелме икәнлеге турында түгел, балаларны һәм яшүсмерләрне тәрбияләү проблемалары турында сөйләшергә тиеш.

4. Шәйхи Маннур:

Мин повестьның «Яшь ленинчы» да басылган өлешен дә, бу әсәргә карата «Соц. Татарстан»да басылган репликаны да укыдым. Газета таләпләреннән һәм мөмкинлекләреннән чыгып, «Күзгә-күз» «Яшь ленинчы»да кыскартып басылган. Шунлыктан әсәрнең кайбер урыннарында өзеклек тә сизелә. Шунлыктан, газета вариантыннан гына чыгып, повестька тулы бәя биреп булмый.

Җәвадның репликасын укыгач, мин повестьтан тәнкыйть ителгән җитешсезлекләрне – «эт күмелгән урыннарны» эзләп карадым. Әмма тапмадым.

Повесть кирәкле темага һәм изге ният белән иҗат ителгән. Автор тормышны шомартып түгел, ничек бар шулай, җитешсезлекләрне тулысынча әйтеп язган. Шунлыктан мин Җ. Тәрҗемановның репликасына аптырап калдым. Җәвад бит әдәбиятның, язучылык профессиясенең үзенчәлекләрен яхшы белә. Үзе дә балалар өчен күп язган кеше.

Безнең бүгенге балаларыбыз инкубатор чебешләре түгел бит. Дөнья, тормыш бүтәнчә бит. Балаларыбыз «аракы» дигән сүзне белмиме, аның семьясында, әйләнә-тирәсендә юкмы ул? Эчүчелек буенча Татарстанның ничәнче урында торганын беләбез без. «Аракы» дигән сүзнең «Яшь ленинчы» да басылуы очраклы да, гаҗәп тә түгел. Беркемне дә гаҗәпләндерми ул бүген. Балалар һәм яшүсмерләр арасында җинаятьчелекнең үсә баруы – борчылырлык хәл. Мондый чакта песием-песием дип кенә язу дөрес булырмы соң? Повестьне бастырып, «Яшь ленинчы» бернинди дә педагогик, эстетик хата эшләмәгән.

«Яшь ленинчы»ны мин Татарстанда чыга торган бөтен газеталарга караганда да яратыбрак укыйм. Ул үз бурычын

бик яхшы үтәп бара. Редакциядә эшләүче иптәшләргә уңыш телим.

5. Рөстәм Мингалимов:

Повестьны мин ике кат укыдым. Реплика басылганчы да, аннан соң да. Шуны әйтәсе килә: карт коммунист Гафур Кәрамов кебек гүзәл образлар балаларга бер дигән үрнәк бит. Әмма Алик кебек бандитлар да бар бит әле дөньяда. Яшүсмерләр исә андыйлардан сак булырга, аларга каршы көрәшергә тиешләр. «Күзгә-күз» менә нәрсәгә өнди.

6. Таһир Нурмөхәммәтов:

Минем үзем укыган әсәрләрнең кыскача эчтәлеген, төп геройларын, автор фикерләрен язып куя торган гадәтем бар. Менә хәзер Аяз Гыйләҗевнең «Күзгә-күз» әсәре турында сүз чыккач, әлеге дәфтәрне тагын кулыма алдым.

В. Быковның иң көчле әсәре – «Сотников». Сотников әсәр башында бик чирләшкә, мескен партизан итеп тасвирлана. Ул отряд командирына үзенең авыру икәнен дә әйтми, сазлыкта яшеренеп яткан ач партизаннарга ашамлык юнәтү нияте белән авылларга китә. Аның иптәше Рыбак исә – бик таза, сугышырга оста партизан. Ул – фикере белән дә уңай, яхшы кеше кебек. Ләкин иң авыр моментта, полицайлар кулына эләккәч, намусы, вөҗданы каршында: «Җаныңмы, илеңме кадерлерәк?» – дигән сорау килеп тугач, кайчандыр вак җинаятьче, хулиган булган Рыбак полицайлар ягына күчә һәм корыч рухлы Сотниковның палачына әверелә.

Яки В. Астафьевның «Кража»сын алып карагыз. Аның бу әсәре А. Гыйләҗевнең «Күзгә-күз» әсәре белән аваздаш.

В. Астафьевта балалар кассадан урлаган акчаны морҗа эченә яшереп куялар. Билгеле инде, детдомга милиция килеп төшә, бөтен нәрсәне актарып тентү ясый, ләкин акчаны таба алмый. Моңарчы аракысын да чөмереп, кәнфитен дә суырып өлгергән нәни караклар тантана итәләр. Шундый дәрәҗәгә җитәләр, арадан берсе каешын ычкындырып, милиция начальнигына арт кояшын ялтыратып күрсәтә.

Мин Астафьев турында тәнкыйть материалларын да караштырдым. Ләкин, «безнең совет милициясен мыскыл итә ул» дип, кемнең дә булса авторны тәнкыйтьләп чыкканын күрмәдем. Чөнки «Кража» әсәре, А. Гыйләҗевнең повес-

те кебек үк, милиция работниклары турында түгел, яшүсмерләрне якты тормышка кайтару турында, тәрбиянең әһәмияте турында.

Бер көнне безнең реплика авторы белән ике арада кыска гына сөйләшү булып алды:

– Кара син аны, Җәүдәткә кияү пәрәмәче ашата бит ул...– диде автор.

– Ашатса ни булган, татар халык ашларының исемнәрен дә телгә алырга ярамыймы әллә хәзер? – дидем мин.

– Син әле кайбер нәрсәләрне аңлап җиткермисең. Мин сиңа дус итеп кенә әйтәм. Менә ни өчен Җәүдәтнең караваты шыгырдый?..

Бүтәнен әйтеп тормыйча, янә Астафьевка килик: детдомга бәләкәй генә эвеню кызын китерәләр. Ятим бала. Ике браконьер аучы аны җенси яктан файдаланыр өчен тоткан булганнар. Бу хәлне белгәннән соң, балалар йорты мөдире:

– Кешеләр, бу ни эш? Бу нинди кыргыйлык?! – дип өзгәләнә.

Аяз Гыйләҗевнең әсәрендәге караваат шыгырдаудан да әллә нинди нәтиҗә чыгарырга торалар, ә менә Астафьев үзенең миллионлаган укучыларына, яшь укучыларга, югарыда күрсәтелгән вәхшилекне ачып салудан да курыкмый.

Шуны да онытмыйк: җинаятьтән – хыянәткә, Ватаныңны сатуга – бер адым. Ә совет әдәбиятының Ватан кайгысын моңарчы бер генә минутка да онытканы юк әле.

Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышта яшүсмерләр өчен бездә китаплар аз чыгарылуы турында аз әйтелде. Балалар әдәбиятын даими рәвештә кайгыртып торучы тәнкыйтьчеләребез дә юк. Болар турында җитдирәк уйланырга кирәк безгә.

7. Фатих Хөсни:

Җәвадның репликасын укыгач, миндә: «Тәрҗеманов иптәш әдәбиятны шомартырга чакырмыймы? Лакировкага өндәмиме?» – дигән сорау туды. Җәвадның бик хәвефле, тревожный итеп чәчрәп чыгуы да миңа ошамады. Тулаем алганда, әсәрдә «тревога сугарлык» әйбер тапмадым мин. Киресенчә, гыйбрәтле нәрсәләр күрдем. Баткаклыкка ничек кереп китә яшүсмер? Бу – гыйбрәтле хәл. Яшь буынны тәр-

бияләү өчен кирәк ул. Хәтерегезгә төшерегез: башта Җәүдәтне балык тотарга чакыралар. Анда эчәләр. Аннары егеткә водокачка янына килергә кушалар. Шулай итеп, Аликлар Җәүдәтне, әкрен-әкрен, тормыш баткагына сөйриләр. Яшь буынны ялгыш юлга басудан тыя торган вакыйгалар болар. Шулай да әсәрне газетага басар алдыннан редакцияләргә кирәк иде. Гафур Кәрамовны аттыру акланмаган. Аннары әдәбиятта һаман кулланылып килгән шундый аксиома бар: «Добродетель торжествует, зло наказывается». Әсәрдә бу – юк. Китап итеп чыгарганда обязательно карарга кирәк.

*Залдан реплика*: әсәрнең ахырында Алик белән Моратны кулга алалар һәм җавапка тарталар бит.

8. Фатыйма Ибраһимова (филология фәннәре кандидаты):

Әсәрне мин газетадан даими укып бардым. Миңа бигрәк тә Җәүдәт образының бирелеше ошады. Аның эчке кичерешләре тулы һәм матур бирелгән. Бу повесть безнең балалар әдәбиятына яңалык алып килгән кебек тоелды миңа. Ә Гафур Кәрамов образын тулыландырасы бар әле.

9. Хәсән Сарьян:

Мин башта Җәвад Тәрҗемановның газетада басылган репликасын укыдым. Бүген исә – повестьның үзен. «Яшь ленинчы»да басылган вариантын, билгеле. Реплика авторы повестьтагы кара җөмләләрне генә җыеп алган. Әсәрдә исә алар персонажлар сөйләменә, вакыйгаларга бәйләнешле рәвештә бирeләләр. Димәк, Җәвад гайбәт сөйли.

Миңа калса, әсәрнең ахыры ышандырып җиткерми кебек. Әмма, редакциядә эшләүче авторларның әйтүенә караганда, повесть кыскартып басылган. Бәлки, шуның нәтиҗәседер.

Наза – күңелдә кала торган образ. Әмма аны активрак итәсе иде.

Кыскасы, яшүсмерләр турында журналыбыз юк икән, димәк, «Яшь ленинчы» әсәрне басып дөрес эшләгән.

10. Җәвад Тәрҗеманов:

Мин ни өчен реплика язарга мәҗбүр булдым соң? Әсәрдә Аликлар җиңеп чыга бит. Гафур Кәрамовны үтерү вакыйгасы бөтенләй кирәкми. Каракларның образлары исә артык күпертеп бирелә. Алик һәрвакыт галстуктан йөри, культура-

лы, кешеләр белән дә оста аралаша. Ә Җәүдәт – йомыкый, тәҗрибәсез.

Балалар өчен мондый әсәрләр язарга кирәкми, зурлар өчен язарга кирәк. Эчүчелекне, хулиганлыкны балалар гына бетерә алмый бит.

11. Гомәр Бәширов:

Җәвад Тәрҗемановның чыгышы репликасыннан аерылмады. Турысын әйтим: мин бу чыгышны аңламадым. Җәвад: «Әсәрдә бер генә дә уңай герой юк»,– диде. Мәгълүм ки, әдәбиятта төрле алымнар яшәп килә. Уңай геройларны сурәтләп, язучы «менә нинди булырга кирәк» ди. Тискәре геройлар тудырып, язучы «болар кебек булмагыз» ди бит. Язучы булган кеше моны гына аңларга тиеш. Җәвад Тәрҗеманов исә аңларга да теләми. Әсәрдәге кара якларны санап китә дә: «Автор нәрсә әйтергә тели моның белән?» – ди. Язучыга яла ягу бит бу.

Аяз Гыйләҗев геройны ялгышулардан сакларга, кисәтергә тырыша. Бернинди тәҗрибәсез яшүсмер Җәүдәтнең, каткат кыйналса да, Аликларга каршы көрәшүе әйбәт. Наза да, аның әтисе Гафур да – әйбәт кешеләр, безнең заманда, социалистик җәмгыять шартларында тәрбияләнгән кешеләр.

Әсәр үз бурычын үтәгән. «Яшь ленинчы» газетасы исә повестьне басып дөрес эшләгән. Әлбәттә, әсәрдә кайбер кытыршылыклар бардыр. Анысы – икенче мәсьәлә.

«Яшь ленинчы» – минем яраткан газетам. Табигатьне саклау мәсьәләсендә булсын, балалар алдында торган бүтән мәсьәләләрне хәл иткәндә булсын – газета үз эшен белеп башкара, заман белән бергә атлый. Анда басылган мәкаләләр исә җыйнак, конкрет һәм җиңел тел белән языла.

12. Фәрваз Миңнуллин (тәнкыйтьче):

Балалар әдәбиятының төп бурычы – яшь буынны коммунизм җәмгыятенә лаеклы кешеләр итеп тәрбияләү. Бу – бәхәссез хакыйкать. Бу кадәресе белән һәммәбез дә килешәбез. Ә һәрьяктан килгән андый кешене ничек тәрбияләргә? Бәхәс әнә шул төштә башлана. Җ. Тәрҗеманов, баланы уңай күренешләр, матур кешеләр үрнәгендә тәрбияләргә кирәк, ди. Бу – һич тә яңа караш һәм Тәрҗеманов уйлап тапкан нәрсә түгел. Күптән билгеле караш. Тәрҗеманов шул нок-

тадан чыгып, А. Гыйләҗев повестен сүтеп аткан. Әсәрнең үзен укымаган килеш Тәрҗеманов мәкаләсенә тотынсаң, ул чыннан да сине ышандыра. Реплика авторы, үз алдына мәгълүм максат куеп, әсәрдән ямьсез хисләр уятырлык җөмләләр җыеп чыккан, аларны үзенчә компоновать иткән. Аяз Гыйләҗевне мактарга теләгән кеше исә шул ук әсәрдән ифрат якты, җылы җөмләләр җыеп чыга ала. һәм укучыларны Тәрҗеманов раслаганнарның нәкъ киресенә ышандырачак. Минемчә, боларның берсе дә – чын һәм җитди тәнкыйть түгел. Чын тәнкыйть әсәрнең гомуми яңгырашына, төп пафосына, авторның әйтергә теләгән төп фикеренә, ниһаять, шуларның нихәтле сәнгатьчә эшләнгән булуына таянып эш итәргә тиеш. Җ. Тәрҗеманов мәкаләсенә нәкъ шул җитми. Чөнки аның максаты бу түгел. Аның максаты – «балалар әдәбияты болай булмаска тиеш» дип расларга тырышу.

Инде әсәргә объектив якын килсәк, менә нәрсәләр күрәбез. Беренчедән, повестьта ямьсез күренешләр, ямьсез телле урыннар һич тә тулып ятмый һәм күңелдә авыр хис уятмый. Тәрҗеманов аларны бер урынга җыйган гына. Шуңа күрә авыр. Аннан соң, андый урыннар әсәрдә башка максатларга хезмәт итә. Алар Аликлар дөньясыннан җирәндерү, шул даирәгә нәфрәт тәрбияләү өчен кирәк. Әгәр Моратлар йортындагы кыргыйларча кыйнау булмаса, ихтимал, Җәүдәт караклар шайкасына каршы көрәшкә чыгарга җөрьәт тә итмәгән булыр иде. Бу – психологик момент. Автор дөрес тоткан. Кабатлап әйтәм, Тәрҗеманов каршы чыккан, ятратмаган күренешләр миндә, укучы буларак, ямьсез тойгы түгел, Аликларга карата нәфрәт уятты, аларга каршы көрәшәсе килү тойгысы уятты. Әсәрнең иң көчле, иң файдалы ягы шунда, минемчә.

Бер кызып киткәч, Тәрҗеманов повестьнең идеясен дә бозып аңлаткан. «Һәркем үзе өчен!» – бу әсәрдә шундый идея уздырыла, ди Тәрҗеманов. Бу – ялгыш фикер. Әсәрнең идеясе мондый түгел. Бу – самими һәм беркатлы малай Җәүдәтнең карашы. Автор түгел, Җәүдәт шулай уйлый. Шулай уйлап ялгыша да, һәм бу ялгышы аңа бик кыйммәткә төшә. А. Гыйләҗев повесте нәкъ менә «һәркем үзе өчен!» дигән фикернең ялгыш булуын дәлилләү өчен язылган!

Алайса, балалар әдәбияты нинди булырга тиеш соң? Кире мисаллар үрнәгендә тәрбияләргә тиешмени?

Зурлар әдәбиятына да, яшьләр әдәбиятына да таләп бер: әдәбият кешене тормыштан алынган мисаллар, тормышчан мисаллар нигезендә тәрбияләргә тиеш. Әдәбиятның мең еллык үсеше менә шул турыда сөйли. А. Гыйләҗев исә укучыларны нәкъ менә шундый тормышчан мисаллар үрнәгендә тәрбияләргә була. Повестьның «Күзгә-күз» дип аталуы үзе үк аның партияле әсәр булуы турында сөйли.

Повестьнең «Яшь ленинчы»да басылган вариантында очы-очка ялганып җитмәгән урыннар бар, билгеле. Бәлки, кыскарту нәтиҗәседер. Повестьны китап итеп чыгарганда әсәрнең биредә әйтелгән кимчелекләре бетерелергә тиеш.

Бу җыелышта сөйләшкәннәребез «Социалистик Татарстан» газетасына һәм «Күзгә-күз» повесты турында анда басылган репликага җавабыбыз булыр дип уйлыйм мин.

Проза һәм балалар әдәбияты секцияләренең берләштерелгән җыелышы, югарыда сөйләгәннәрдән чыгып:

1. Аяз Гыйләҗевнең «Күзгә-күз» повестен нигездә уңышлы дип бәяли.

2. Повестьны «Яшь ленинчы»да бастырып чыгару педагогик яктан да, идея-политик яктан да дөрес дип саный.

3. Повестьны китап итеп чыгарганда, әсәрнең бу җыелышта күрсәтелгән кимчелекләрен бетерергә тәкъдим итә.

Председатель: Р. Фәйзуллин (подпись)
Секретарьлар: Х. Халиков (подпись)
Ә. Гаффаров (подпись)

*Мухаммет Магдеев*

# О творчестве А. Гилязова[1]

*(Выступление на телевидении, декабрь 1977)*

1. Если уж речь зашла о прозаике Гилязеве, то, мне кажется, прежде всего, нужно ответить его индивидуальные качества как автора многих повестей, рассказов и романа. Сказать о том, что Гилязев всегда активен, всегда патриотичен и гражданственен – это значит, не сказать о нем ничего. А кто из наших писателей не активен, не патриотичен и не гражданственен в своих произведениях?

Своеобразие Гилязева, как прозаика, мне кажется, в том, что в прозе он выступает каждый раз в новой форме. Речь идет не о сюжетной линии, в этом аспекте, как показывает литературный опыт, писатель не повторяется, каждый раз он прокладывает новую борозду. Но не каждому удается не повторяться внутри своего творчества в смысле композиции или, как говорят теперь, архитектоники произведения. Аяз же Гилязев в каждой повести, рассказе выступает на новом ключе. У него и тема, и композиция, и решение проблемы каждый раз: неожиданно и ново. Не только внутри одного жанра, но и вообще в своем творчестве Аяз работает с переключением: от прозы он переходит к драматургии, от драматургии к публицистике и т.д. Такая, я сказал бы, ритмическая перемена в творчестве дает писателю возможность осмыслить и оценить свои произведения: драмы – глазами прозаика, прозу – глазами драматурга.

2. Какие черты характерны для прозы Гилязева? Прежде всего, надо подчеркнуть, что Гилязев пришел в литературу вполне сознавая, что он выбрал путь очень сложный, может быть, самый трудный. Почему я называю путь писателя самым трудным и сложным? Потому что, как подчеркнул однажды известный советский прозаик Ф. Абрамов, литература – это всегда борьба, это – разговор о жизни, о народе, о Родине, о времени по очень большому счету. Литература

[1] Тапшыруга чыкмаган телетапшыру өчен әзерләнгән материал. Архивка тапшырылган датасы: 20.01.1978.

для Гилязева – не ремесло, не слава, о которой не прочь помечтать иной начинающий молодой писатель, литература для него – вся жизнь, смысл его жизни. Его творчество определяет страстная любовь к своему предмету, по крайней мере, без искреннего, правдивого отношения к нему, нет искусства.

Гилязев часто обращается к деревенской теме – к деревне военного времени. Мне кажется, в этой теме он чувствует себя свободнее. Оно и понятно, вполне естественно, если учесть, что формирование личности у нашего поколения началось в атмосфере великого стремления народа победить фашизм. Каждый писатель должен работать в том жанре, где у него больше отдачи. Наиболее удачным произведением в этом плане я назвал бы его повесть «Весенние караваны», своим внутренним пафосом похожую на одну из последних повестей Айтматова «Ранние журавли». В «Весенних караванах» женщина-колхозница с больным сердцем отправляется в трудный долгий путь вместе с молодежью – они на санках везут из дальней глубинки семена для колхоза – и в пути она умирает. Конечно, автор мог «сохранить» ей жизнь, ее могли подвезти, подлечить и отправить домой... На законы искусства требовали, чтобы она погибла. Погибла во имя светлого будущего молодежи – в повести мы видим молодых колхозников Ибрагима и Адилю, застенчиво любящих друг друга. Автор утверждаем красоту борьбы и смысл жизни через смерть. Хоть и погибает эта больная женщина из-за головотяпства какого-то бюрократа, но смерть ее звучит как бы утверждением жизни. Эта женщина в тылу совершает подвиг, какой совершали на фронте ее соседи, односельчане. Впрочем, для истории искусства такое решение смысла жизни не новость: взять, например, героев повести Айтматова «Пегий пес, бегущий краем моря» – герои гибнут во имя сохранения жизни мальчику по имени Кириск. В литературе такое решение проблемы – красота жизни – встречается часто. Но в татарской литературе такое встречается не часто, правда, поколение, к которому принадлежит Гилязев – это Ахунов, Баянов, Н. Фаттах, Х. Сарьян – в своих творческих исканиях за последние годы, можно сказать, отошли от шаблона в ли-

тературе, когда герои обязательно побеждают и произведение завершается свадьбой и тостами.

В искусстве социалистического реализма и трагическое проникнуто оптимизмом, это – бесспорное положение. Короче говоря, А. Гилязев всегда волнует читателей, ни одно его произведение не оставляло читателя равнодушным. Не всегда ему удается стиль, не всегда удачен его герой, не всегда удачно решение проблемы. Но пишет он всегда о том, как говорил драматург Вампилов, «отчего не спится по ночам». Отсюда его усиленное внимание к нашей трудной молодости, которая совпала с грозным временен Великой Отечественной войны. Надо, чтобы сегодняшняя молодежь помнила, на какие жертвы, лишения и тяготы шел наш народ в то время во имя счастья будущего. Это – передача сегодняшнему поколению нравственных ценностей прошлого. В этом Гилязев всегда старается быть правдивым.

3. Кстати, о нравственных ценностях. Как отмечает наша литературная критика, время поставило в качестве центральной главенствующей проблемы жизни и литературного развития последних лет проблему человека и его ценностей. Правда, эта проблема вечная, но новизна ее заключается в отчетливости понимания того, что в нашей жизни по мере движения к коммунизму в геометрической прогрессии возрастает роль нравственных начал. В нескольких своих произведениях последних лет как, например, в повестях «На перепутье», «Повесть о любви и ненависти», в романе «За городом зеленые луга», «С глазу на глаз» Гилязев обращается именно к нравственным проблемам, ищет нравственные качества героя сегодняшнего дня. Не проглядеть бы за сегодняшней внешностью главное, не уступить бы мещанству. В этом аспекте особенно ярко проявилась все позиция писателя в повести «На перепутье», где он выносит суровый приговор душевней черствости и человеческому эгоизму.

## Стенограмма

*выступления переводчика, друга Аяза Гилязова, Арпада Галгоци[1] на международной конференции «Аяз Гилязов и его наследие в мировой и отечественной культуре» (Казань, КФУ, 2018)*

Уважаемые дамы и господа! Мне очень сложно говорить о таких вещах в таких условиях. Особенно тогда, когда я чувствую себя членом одной большой семьи. Пять лет назад я вообще не думал о том, что я хоть когда-нибудь в жизни попаду в Казань. Но чудо случилось: с помощью интернета и современных технологий мы наладили связь. Мы обрели связь с верным другом, с которым мы в суровое, тяжелое время в Караганде камень ломали и в ГУЛАГе сидели. Это была самая тяжелая часть нашей жизни. И я искренне жалею, что мы не смогли, к сожалению, больше встретиться, Аяз ушел раньше из жизни. Я часто думаю о том, как было бы хорошо, когда я прилетел бы в Казань и в составе делегации, которая меня встречает, стоял бы сам Аяз. Я прошу Вас с гордостью думать об Аязе, великом человеке Вашей Родины. Мы всего несколько недель вместе были в лагере, но этого времени было достаточно, чтобы хорошо узнать друг друга. Мы формировали мышление друг друга, помогали друг другу, даровали друг другу веру. Мы подолгу разговаривали по ночам о системе, из-за которой мы оказались в лагере. Я никогда не забуду ту ночь, когда Аяз рассказал мне, как инспектор лагеря – кум – попросил его стать шпионом в лагере. Отказаться подчиниться такому предложению было равносильно приговорить себя к смертной казни в лагере. Но Аяз отказался. Он сказал мне: «Арпад! Для меня совесть ценнее, чем свобода!» Когда я приезжаю в Казань, я всегда думаю об этом, вспоминаю эти слова. Когда сейчас стою перед Вами, то ощущаю, что он стоит рядом и держит меня за руку, что символизирует, что мы хотим стать свободными вместе. И мы стали свободными. Единственное, о чем сожалею, что его нет сегодня с нами. Но в моей душе он всегда со мной. Уважаем и любим память Аяза Гилязова!

---

[1] Арпад Галгоци (1928–2022) – венгр язучысы, тәрҗемәче, Аттила Йожеф, «Палладин» әдәби премияләре лауреаты.

# А. Гыйләҗев образы әдәбиятта

*Арпад Галгоци*

## Язга таба[1]

*(Хикәя)*

Караңгыланды. Казакъ далаларында караңгы искәрмәстән төшә. Сәяси тоткыннардан гыйбарәт өч йөз кешелек колонна, әлбәттә, вакытны ашыктырып, тизрәк «өйгә» кайтырга тели. Анда, артык зур булмаган «үз лагерьларында» аларны хәзер миче ягылган барак, йомшак ятак көтә. Ул гынамы, көн дәвамында арган-талчыккан тоткыннар соңгы вакытларда, махсус кибеткә кереп, ак майдан, колбасадан авыз итә ала, башка төрле тәм-томнар да шунда гына. Акчаң гына булсын! Җәйдән бирле аларга бераз эш хакы да түли башладылар. Ризык төрләндерергә шул сәмәннәр ярап тора. Югыйсә әле кайчан гына кысыр баланда да иң тәмле аш булып тоела иде.

Соңгы айларда галәмәт зур Империядә күз алдына китермәслек үзгәрешләр булып үтте, ачлык-ялангачлыктан интеккән тоткыннар язмышында да әлеге үзгәрешләрнең нәтиҗәсе күренде. Күренмәслек тә түгел — 1953 елның 5 мартында Сталин кушаматын йөрткән Иосиф Джугашвили дигән кансыз җәлладның җаны җәһәннәмгә китте. Дөмекте! Империя халкы, бу хәбәрне ишеткәч, тирән кайгыга төште, әлбәттә, шулай булмыйни — алар әлеге ерткычны кешелек дөньясының Атасы да, Остазы да дип тәмам ышанган иде инде, һәм, бердәм булып, күпсанлы корбаннар хакына, тиз-

---

[1] Галгоци А. Язга таба (Р. Зәйдулла тәрҗемәсе) // Казан утлары.— 2018.— № 3.— 155—157 б.

дән бөтен инсан да бәхет кичереп яшәячәк коммунизмны көтә иде.

Ил башына надан, ләкин гаять тә хәйләкәр Хрущёв килде. Сталинның тугрылыклы аркадашлары бераздан берәм-берәм тарих сәхнәсеннән төшеп калды. Безнең өчен иң мөһиме – Сталин үлгәннән соң, сәяси тоткыннарның хәле сизелерлек җиңеләйде. 1953 елның җәендә тоткыннарны теркәп, фотога төшерә башладылар, ә ноябрьдә инде аларның кайберләрен, төркем-төркем туплап, азат та иттеләр.

Без, күкрәк киереп, иркен суладык. Ләкин барыбызга да азатлык һавасын иснәргә әле иртәрәк иде.

Безнең лагерь Караганда шәһәреннән ерак булмаган Актас дигән урында. Һәр көнне бригадаларны кирпеч лагерена эшкә алып китәләр.

Әйе, казакъ даласында караңгы искәрмәстән тиз төшә. Ләкин без аны һәрвакытта көтеп алабыз. Бу юлы, рәт-рәт тезелеп тормыйча гына, төркем-төркем булып, лагерьга ашыктык. Карлы яңгыр ява башлады. Аяз Гыйләҗев һәм мин алдан йөгерәбез. Аның белән берничә атна элек танышып, дуслашкан идек. Баракта да ятакларыбыз янәшә. Ул сөйләргә ярата, мин исә, аның һәр сүзенә колак салып, адымымны кызулыйм.

Башка дуслары Аязны Алексей дип атаса да, мин аңа Хан Батый дигән яңа кушамат тактым. Ул – Казан университетында укыган белемле, аңлы егет, совет системасының асылына яшьтән үк төшенгән...

Күпмедер эндәшми барганнан соң, Аяз карлыккан тавышы белән минем якка кычкырды:

– Борылып кара әле, затлы банкетка ашыгучы туристларга охшап калганбыз, ә? Менә бит замана! Кайчан гына бишәр-бишәр тезелеп, кулны артка куеп, башны иеп, колоннада тынсыз гына йөри идек; бер адым читкә чыксаң да, конвой ике дә уйламый атып үтерер иде. Җүнләп яшибез генә дигәндә, сине илеңә кайтарып җибәрерләр инде...

– Киресенчә дә булырга мөмкин. Сине кайтармаслармы әле өеңә. Азат иткәндә, төрле сәбәп табалар бит. Ничек булса да, мин сине Венгриядә кунакка көтәм. Тик үзең белән урыс армиясен генә ияртмә!

Бер-беребезнең аркасыннан кага-кага, рәхәтләнеп көлештек. Көтмәгәндә, ун-унбиш адым артта, кырыс тавыш яңгырады:

– Стоять!

Конвойчы сержант безгә бишәр кеше булып рәткә басарга боера иде.

Барыбыз да туктадык. Әйтерсең лә һәркем катып калган иде.

– Көтү кебек барасыз! – дип акырды сержант.– Иманыгызны укытырмын!

– Ул нәрсә, акылдан шашкан мәллә...– дип, татар дустым җилкәсен җыерды.– Сигез айга соңга калган бит болай кычкырырга!

Һәм ул, кинәт борылып, ачы тавыш белән сөрән салды:

– Кузгалмаска! Бер адым да атламаска! Ни шагу!

Без, өнсез калып, татар әмеренә буйсындык. Беркем дә урыныннан кузгалмады. Төптән юан чыккан бер конвойчы колонна алдына йөгерде, урыннарында катып калган, суыкта туңган арестантларны, шеренгага бастырып, алга кумакчы булды. Ләкин Аязның боерыгы катгый иде.

Бер урында басып торгангамы, без туңа башладык. Җилләтеп тә җибәрде. Аркан борылып, бушлатның сырган якасын күтәреп куйдык. Җил сул яктан исә иде, колоннаның уң ягындагы солдатлар нәкъ җилгә каршы басып торырга мәҗбүр. Ә дала җиле ул кышын җелегеңә төшә! Сталин үлеменә иң нык үкенүчеләр бу минутларда шулар булгандыр, мөгаен. Сержант сыны каткан рәтләр буйлап гасаби рәвештә йөрүендә булды. Ул тәмам аптыраушта иде.

– Әй син! Берия сыңары! Ишеттеңме әле, аны Лубянка подвалында стенага терәп атканнар. Дөнья үзгәрде, ә син һаман аңгыра! Бетте сезнең замана. Тәмам!

Колонна койрыгында яңгыраган бу сүзләр безнең очка да килеп ирешстте. Тавышын йомшартырга тырышып, сакчыларның башлыгы кичәге колларга акрын гына endәште:

– Атларга әзерме сез? Аргансыз бит инде, кузгалыгыз.

– Лагерь нәчәлниген чакырыгыз! Ул килгәнче, бер адым да атламыйбыз! – Мин бик тиз танып алдым – бу Фомин

бригадасыннан һәркемгә итагатьле поляк Левандовский! Аңа дуслары, гадәттә, Пан дип кенә эндәшә иде.

Үз кадерләрен үзләре белә башлаган тоткыннар белән каршылыкка керергә гарнизон нәчәлнигенең башына тай типмәгән. Бәхәсләшеп торырга инде соң – төн якынлаша, суык та көчәя бара. Сигез ай элек булсамы?!

Ләкин йомышчыны барыбер лагерьга йөгерттеләр. Егерме минут үттеме-юкмы, нәчәлник килеп тә җитте. Полковник Лебедев үзе! Бер урында таптанучы туңып беткән тоткыннарга ул, ачуын һич тә тышка чыгармыйча, кешечә эндәште:

– Аң булыгыз, кешеләр! Кайтыгыз! Җылынырсыз...

Күрәсең, шул сүзләр генә кирәк иде, колонна лагерьга таба кузгалды. Тик аңарчы кемдер төн караңгылыгына төбәп кычкырып өлгерде:

– Бу сержант бүтән күренмәсен!

Чыннан да, ул сержантны без башка күрмәдек. Ул гына да түгел, безне уң яктан саклаучыларның һәммәсе, битләре өшеп, хастаханәгә эләккән, дип сөйләделәр.

Икенче көнне иртән кояшның ап-ак кар өстендә уйнаган алтын нурларыннан күз чагылды.

Көннәр язга авышкан иде.

*Венгр теленнән Ркаил Зәйдулла тәрҗемәсе*

*Газинур Морат*

## Йәгез, бер дога![1]

Бу дөнья сезнең дә, агай,
Иңнәрдә тора...
Фәрештәләр куәт бирсен –
Йәгез, бер дога!
Ил корабы фарватерда
Утырган комга...
Бурлак булып җигелгәнсез –
Йәгез, бер дога!
Кулларга зынҗыр салынган,
Уйларга – богау...
Зынҗырсыз җыр саулыгына
Йәгез, бер дога!
Исәр заман дулый һаман –
Вата да кора...
Хәрабәләр рухына
Йәгез, бер дога!
Күп яшәлде бисмилласыз –
Кичерсен Ходай...
Сәҗдәгә китәр чак, агай,
Йәгез, бер дога!
Йәгез, бер дога!

*Гамил Афзал*

## Син – бик усал, ач арыслан кебек...

Син – бик усал, ач арыслан кебек,
Усаллыгың җитәр йөз елга.
Юаш кына малай идең элек,
Усаллата икән бу дөнья!

---

[1] Морат Г. Йәгез, бер дога! [шигырь] // Мәдәни җомга.– 1996.– № 6.– 9 февраль.– Б.7.

## Без – тугры!

Эчтек бер чишмәнең суын
Бала чакта.
Гамьсез йөргән айлар, еллар
Калды артта.
Безне заман ничек кенә
Сынамады.
Себерләргә сөрә-сөрә
Кыйнамады?!
Анда да без тугры булдык
Газиз илгә,
Саф, таза җан белән кайттык
Туган җиргә.
Каралтмадык, сүрелтмәдек
Җанда хисне.
Дуслар хисен яхшыртырга
Куйдык көчне.
Ләкин арабызда яши
Ят, көнчеләр,–
Безне ямьсезләргә теләп
Өрүчеләр.
Шомырт кара чәчебезгә
Кунса да кар,
Телебездән беркайчан да
Чыкмас үч, зар.
Читкә какмас һич тә безне
Чукмарлыбыз:
Дуска – сердәш, дошманнарга
Чукмарлы без.

## Мостафа...[1]

Һәр төбәкнең Муллины
утызынчы елларда
ярлы-гидай һәр мужик:
– Мин җирле,– дип торганда,
өмет сабын сындырып,
кылыч бирде кулларга:
– Туганыңны чак,– диде,–
Туганыңны чап,– диде...
Төгәл-кырыс кулланма...
Һәр төбәкнең Мостафасы
утызынчы елларда
халыкның каш-күз арасын
ядрә белән ерганда,
юылды уелган җаннар,
чи ит белән буталып,
сузылды утлы еландай
оешкан кан тутыгы,
Черек күлне тутырып...
Мостафаның, Муллинның
оныклары туганда,
бабалары кулланмасын
өлге итеп куйганда,
оешкан кан тутыгына
күбәләкләр кунганда,
Черек күлнең аръягында
Ккызарып
Ай тулганда,
Сискәнеп тартылды ХӘТЕР...

[1] Мирза М. Сискәнеп тартылды хәтер: [А. Гыйләҗевнең «Мостафа» әсәрен укыгач язылган шигырь] // Мәдәни җомга.– 1996.– № 38.– 20 сентябрь.– Б.7.

## Акрын гына карлар төшә өскә…[1]

Акрын гына карлар төшә өскә,
Офыккача тоташ япан кыр…
Учак шәүләләре сикерешә,
Бер кыз көлеп куя кайдадыр.

Ә аксакал карлар хозурында,
Алмаштырып булмый холыкны.
Азатлыкны тою мөмкинмени,
Татымасаң әгәр коллыкны?

Янәшәдә мәш киләләр ишләр,
Кем ул мылтык төзи киеккә?
Балта таушы…
Тигезлиләр тагын –
Үскән кемдер бер баш биеккә.

Татар имән сыман беркатлы ул:
Тамырларга балта тигәндә,
Горурланып аваз бирә кәүсә:
«Сабы безнеке, – дип, – имәннән!»

Акрын гына карлар төшә өскә,
Офыккача тоташ япан кыр.
Монда Тукай ауган, монда Гаяз
Буран ярып алга баргандыр.

Шагыйрьләрне
Болгар бабайлар ук
Хөрмәт иткән, кулга нан биргән,
«Аның урыны Тәңре янында», – дип,
Муенына элмәк кидергән.

---

[1] Зәйдулла Р. Акрын гына карлар төшә өскә... [шигырь] // Идел. – 2003. – 1. – Б.31.

Офыккача тоташ аклык бүген,
Ирексездән җаннарга йога.
Аксакалның эзләренә карыйм
Һәм кабатлыйм: йәгез, бер дога!..

Тып-тын кала тирә-юнем шулчак,
Күздән тамган яшем ник ачы?
Иренемдә юкса Ясин түгел,
Исән үтәсе юл догасы.

*1997*

***Сибгат Хәким***

## Язгы кәрваннар

Сугыштан соң икенче яз, моңсу
Язы иде кырык алтының.
Без чанада икәү, бездән башка
Эзе дә юк кырда атлының.
Абый белән икәү, озата мине,
Аты ябык, арык ат иде,
Минем күңелем кебек, әкрен-әкрен
Эреп барган йомшак март иде.
Сугыштан соң күренеп китү өчен
Кайткан идем, юлым – Арчага.
Тик без генә атлы, сугыштан соң
Калган бары бер ат, бер чана.
Безнең атның курка-өркәсе юк,
Дилбегәне абый буш тоткан.
Икенче бер, бүтән дөньядан,
Ак кар дөньясыннан, бушлыктан,
Кинәт кенә пәйда булды алар:
Ни икәнен сөеп назлауның
Онытып күптән, авыр чана тартып,
Төркеме күк киек казларның,
Хатын-кызлар килә иде тезелеп,

Кычкырдылар: «Ал,– дип,– атыңны...»
Юк, сукмады абый, әйтерсең ат
Оятыннан читкә атылды.
Оятымнан мин чанадан төштем,
Йөрәгемне арыш тырнады;
Алар тартып кайткан чаналарда
Йоклый иде арыш кырлары.
Йоклый иде бодай басулары,
Йоклый иде яшел дулкыннар...
Чәчми калсаң әгәр, шушы кырлар
Гомер буе, беләм, сулкылдар.
Атны абый өйгә таба борды,
Атка җиңел хәзер, ат чаба.
Үземә дә җиңел иде минем,
Мин җәяүләп киттем Арчага.
Горур йөзләр, күзләр, ул карашлар
Күңелемдә язылып калганнар.
Зәңгәр күккә горур башны чөеп,
Бара юлдан язгы кәрваннар.

*Шәриф Биккол*[1]

## Аяз Гыйләҗевкә

«Күрәләтә безне рәнҗеткән» дип
Каргап булмый язмыш-шельманы,
Бер табында бик еш утырырга
Ходай безгә насыйп кылмады.
Тик мин: «Биргәнеңә шөкер!» – димен.–
Бәндәләрдә төрле талым бар:
Җилләтеп тә бетәр иде, бәлкем,
Бик еш булса уртак табыннар...
Җитмәсә дә ярты дистәгә дә
(Тылсым алар, серле фал алар!),
Бергә күңел ачкан бу минутлар
Асылыңны ачып салдылар.
Икеләнеп тормый тарафыңа,
Юнәлттем мин күңел җилкәнен:
Мин бит инде саф алтынны җиздән
Аерырлык яшькә җиткәнмен!
Шундый хакыйкать бар: юнь ир белән
Бер утырулары – бер гомер.
Хак сүз икән: йөрәк учагына
Син өстәдең тере бер күмер.
Бу заманда – өмет өзгән мәлдә
Җанга ямь-юаныч табудан,
Еш, димәем, булсын әле алда
Бергә утырачак табыннар!
Моңарчы син серле китап идең,
Инде байтак бите укылган...
Болай уксыңдыр дип белмәгән идем,
Шәп кешесең икән, чукынган!

*Переделкино, 1992*

[1] Шәриф Сәгадәтулла улы Биккулов (1924–1995) – шагыйрь.

## Уйландырасың…

*Аяз Гыйләҗевкә*

Уйландырасың,
уйландырасың.
Син беләсең милләт кыйбласын.
Ай калкасын,
Кояш чыгасын,
бәхет сәгате илдә сугасын.
Сокландырасың,
Таң калдырасың.
Күз алдында
язгы гөлдәй,
аяз көндәй балкып торасың.

Тылсымлы каләм синең кулда.
Синең уйлар
чишмә буенда,
яшел болында.

Синең хакка дога укып,
каршылыйм туган көнеңне.
Синең күңел, синең күгең
Киек Каз Юлы түгелме?

Уйландырасың,
уяндырасың,
сокландырасың.
Өч аршын җирне генә түгел,
бар Җир шарын
ТАТАР КЫЙБЛАСЫНА БОРАСЫҢ.

*1998, 17 гыйнвар*

***

«Урамнар артында яшел болын»
*А. Гыйләҗев*

Урамнар артында яшел болын,
Аранны кимерә яшь колын.
Аранда тилмерә яшь колын:
«Урамнар артында яшел болын...
Урамнар артында яшел болын...»

Авылда көнозын бер аваз:
Тук та тук гел чалгы чүкиләр.
Абзыйлар, колынны онытып,
Көнкүреш бурычын үтиләр.

Яшь кызлар июньдәй көләчләр,
Урамнан узалар фырт кына.
Кызларга июньнән дәрт кирәк,
Колының кирәкме чуртыма.

Чирәмдә чал чәчле бер бабай,
Колынын, болынын онытып,
Тагын бер өч елга җитсен дип,
Нур җыя кояшка йөз тотып.

Авылда көләч бер көй –
Кешеләр җырлыйлар җәй җырын.
«Урамнар ар-тын-да я-шел бо-о-о-лын...»

Җыр тынган арада каяндыр
Дөп тә дөп бер аваз ишетелә.
Бу шулай аранда яшь колын
Аягын канатып тибенә.

Тибенә, әйтергә теле юк.
Аранны кимерә яшь колын.
Нишләсен әйтергә теле юк:
«Урамнар артында яшел болын,
Урамнар артында яшел болын...»

*1974*

## Эчтәлек

*Миләүшә Хәбетдинова.* Кереш сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Аяз Гыйләҗевнең автобиографик язмалары . . . . . . . . . . . . . . 6
Үзем турында үзем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Балачак сукмаклары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Дөнья агышына без бер буын булып килеп кердек . . . . . 30
Сүз ачыклагычы өчен аз-маз хатирәләр . . . . . . . . . . . . . 33
Тәкъдирдә язганы шул булгандыр... . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Авыл... Авылдан «Олы юл»га . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Эзләремне эзләдем... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Заман мине узып бара . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .131
Үзем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .137
Аяз Гыйләҗевнең хатлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
*Миләүшә Хәбетдинова.* «Хат — сәнгатьнең бер төре ул» (А. Гыйләҗев) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Әңгәмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 264
Бүгенге әдәбиятта замандаш образы . . . . . . . . . . . . . . . 264
Тормыш чынбарлыгын исбатлап . . . . . . . . . . . . . . . . . . 268
Йәгез, бер дога! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 276
Яшьлек дусларым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 285
Татарстан язучыларының XII съезды алдыннан . . . . . . . 291
«Я испытываю угрызения совести» . . . . . . . . . . . . . . . . 293
«Әдипнең кадере бетте...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 299
Здесь живёт писатель . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 307
«Я никогда свободно не дышал» . . . . . . . . . . . . . . . . . . .311
Гомер көзеннән әңгәмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .316
«Авылда яшәсәк, без 10 малай алып кайтасы идек» . . . . 327
Көндәлекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .331
*Миләүшә Хәбетдинова.* «Уйларның төрмәсеннән котылу» ысулы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .331
Мин шулай уйлыйм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 333
Кәкре агачтан туры күләгә төшми... . . . . . . . . . . . . . . . 353
Көндәлекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 359
Аяз Гыйләҗевнең әдәби тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 420
Ә син үзең кем, укучы? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 420

Халыклар күңеленә үтеп керик . . . . . . . . . . . . . . . . . 433
Драматургия, театр һәм тамашачы... . . . . . . . . . . . . . 441
Үкенечкә калмасын! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 469
Җан авазы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .481
Имән чикләвеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 492
Казан, Казаным!.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 506
Рухи яңарыш көткәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .516
Хатирәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 522
*Гариф Ахунов, Ркаил Зайдулла*. Как родилась фальшивая легенда? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 522
*Шамил Рәкыйпов*. Юлбарыслар шундый булсын! . . . . . . 527
*Ида Андреева*. Мои воспоминания о годах студенчества в стенах Казанского университета . . . . 540
*Разил Вәлиев*. Гомеремнең аяз көннәре... . . . . . . . . . . . 546
*Альтер Литвин*. Күптәнге дуска хат . . . . . . . . . . . . . . 552
*Минтимер Шәймиев*. Сүзен кистереп әйтә белде . . . . . . 563
*Марсель Галиев*. Оҗмах бакчалары хозуры . . . . . . . . . . 565
*Тәлгать Галиуллин*. «Өч баһадир» һәм бер тәнкыйтьче турында риваять» . . . . . . . . . . . . . . . . .573
*Ринат Мөхәммәдиев*. Аяз Гыйләҗев әле дә безнең арада... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 603
*Искәндәр Гыйләҗев*. Минем әтием Аяз Гыйләҗев . . . . . . .610
*Мансур Гыйләҗев*. Әтием . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .615
*Рәшат Гыйләҗев*. Әтием турында . . . . . . . . . . . . . . . . 621
Документлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 625
А. Гыйләҗев образы әдәбиятта . . . . . . . . . . . . . . . . . . 657
*Арпад Галгоци*. Язга таба . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 657
*Газинур Морат*. Йәгез, бер дога! . . . . . . . . . . . . . . . . . .661
*Гамил Афзал*. Син – бик усал, ач арыслан кебек... . . . . . .661
*Әзһәр Габиди*. Без – тугры! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 662
*Мөхәммәт Мирза*. Мостафа... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 663
*Ркаил Зәйдулла*. Акрын гына карлар төшә өскә... . . . . . . 664
*Сибгат Хәким*. Язгы кәрваннар . . . . . . . . . . . . . . . . . . 665
*Шәриф Биккол*. Аяз Гыйләҗевкә . . . . . . . . . . . . . . . . . 667
*Кави Латыйп*. Уйландырасың... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 668
*Гәрәй Рәхим*. «Урамнар артында яшел болын...» . . . . . . . 669

*Китапта Аяз Гыйләҗевнең шәхси архивыннан алынган фотоиллюстрацияләр һәм документлар файдаланылды.*

16+ Знак информационной продукции согласно ФЗ от 29.12.2010 г. №436-ФЗ

Научно-популярное издание

**Аяз Гилязов: научно-популярный сборник**

Ответственный за выпуск: *Фуат Рафиков*
Художественное оформление: *Рамиль Миннуллин*
Компьютерная верстка: *Йолдыз Нуриева*
Дизайн обложки: *Григорий Эйдинов*
Корректор: *Нурзида Нотфуллина*

Формат 84х108 1/32. Усл. печ. листов 35,28
Бумага офсетная. Тираж 1500 экз. Заказ №

Оригинал-макет подготовлен с помощью пакета програм Jahat™.

Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленного электронного оригинал-макета в типографии филиала ОАО «ТАТМЕДИА» ПИК «Идел-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2. e-mail: idelpress@mail.ru

9 785902 783657



**Мирсәет һәм Мөгаттәрә Гыйләҗевләр уллары белән:**
**Аяз (унда), Алмаз һәм Азат (артта)**



Аяз Гыйләҗев энесе Алмаз белән. 1937, 14 июнь



Аяз (сулда) абыйсы Азат белән



Язучының Урта Багражда әти-әнисе яшәгән мәктәп ихатасындагы хөкүмәт йорты



РСФСР

Народный Комиссариат Просвещения

СВИДЕТЕЛЬСТВО


Настоящее свидетельство выдано Гилязев Аяз, родивше[муся] в 1928 году, в том, что он обучался в В. Багряж начальной школе ... окончил полный курс этой школы и обнаружил при отличном поведении следующие знания:

по тат. языку — отлично
по русскому языку — отлично
по арифметике — отлично
по естествознанию — отлично
по географии — отлично
по истории — отлично
по рисованию — хорошо
по физкультуре — отлично

Заведующий школой

Учитель

Аяз Гыйләҗевнең башлангыч мәктәпне бетерү турындагы таныклыгы



Күчерү таныклыгы.

Бу таныклык шуны расларга бирелде: Гиләҗев Аяз 1939/40 нчы уку елында Югары Баграҗ авылы урта мәктәбенең 5 нче „а" классында укып, түбәндәге белемнәр (бәяләр) алып 6 нчы класска күчерелде.


5 июнь 40 ел.

| Фәннәр | | белемнәр | Фәннәр | белемнәр |
| --- | --- | --- | --- | --- |
| Ана теле | телдән | отлично | Арифметика | отлично |
| | язма | отлично | География | отлично |
| | әдәбият | отлично | Ботаника | отлично |
| Рус теле | телдән | отлично | Тарих | отлично |
| | язма | отлично | Рәсем | отлично |
| | әдәбият | отлично | Физкультура | отлично |
| Немец теле | телдән | отлично | Үз-үзен тотышы | отлично |
| | язма | отлично | | |

Мәктәп директоры

Класс җитәкчесе

Аяз Гыйләҗевне 5 сыйныфтан 6 сыйныфка күчерү турындагы таныклык



Казанский Государственный Университет имени В. И. Ульянова-Ленина

„14" VIII 1948 г.

№ 57

СПРАВКА

Дана тов Гилязову А. М.

в том, что он сдал все экзамены в Казанский Университет и направляется по месту жительства до особого вызова.

Ответ. секретарь приемной комиссии

1847

Аяз Гыйләҗевнең Казан дәүләт университетына керү турында белешмәсе



**Университеттагы төркемдәш дуслары белән: Сулдан уңга: ?, Аяз Гыйләҗев, Әбрар Кәримуллин, Нил Юзиев. 1949 ел, 16 февраль**



**Аяз Гыйләҗев – тоткынлыкта, Караганда янындагы шахта төзелешендә кочегар. 1954, 9 декабрь**







**Тоткынлыкта Арпад Галгоци ясаган Аяз Гыйләҗев портретлары. 1953, 1954**



**Нәкыя Гыймадиеваның Аяз Гыйләҗев үтенече белән лагерьга җибәргән фотосы. 1955, февраль**



**Аязның, тоткынлыктан котылып, Казанга кайткан вакыты. 1956**




14 декабрь 1950 ел.

Исәнмесез!

Юлдан беренче хатым. Үзем исән-сау, сәламәтлегем яхшы. 7 декабрьдә Казаннан киттем. Кая барып урнашу билгеле түгел, шулай да Казахстанда Караганда тирәсендә калдырырлар кебек. Урынга барып урнашу белән хат язармын. Минем өчен кайгырмагыз. Исән булгач бер кайчан күрешербез әле. Ашау-эчү яклары әле әйбәт тора. Кәефем яхшы. Тик сезнең хәбәрләрне күптән ишетмәгәнгә күңелдә бер вакыт төрле сагыш тора. Хәзер [illegible] Миңа әле хат язмагыз.

Сәлам белән
улыгыз Аяз.



19 декабрь 54 ел.

Сөеклем Җәкия!

Сиңа һәм сезнең барыгызга, [illegible] түтигә, Раягә, [illegible] үземнең туганлык сәламнәремне җибәрәм һәм барыгызны да Яңа ел белән котлыйм. Сиңа атап 22 ноябрьдә хат язган булсам да, нигәдер җавап язмадыгыз. Безгә теләсә кадәр хат язарга рөхсәт итәләр, җавапларны тапшыралар, [illegible] алырга да мөмкин. Сиңа [illegible] язу кыен булса, зинһар [illegible] русча яз. Кайда эшлисең, [illegible] ничек, гомумән югары [illegible] Әхмәтләрдә нинди яңалыклар бар? [illegible], сезне бик сагынам. 55 ел минем өчен [illegible] ел, бу елда мин [illegible] булмагаемын. Тизрәк кайтып [illegible] сезнең яннарга!

Сәлам!


[illegible] миңа хат язарга, мине бөтенләй онытып бетергәнсеңдер әле. [illegible] Якын араларда сиңа фоторәсемемне җибәрәмен.

Хат көтеп абыең Аяз.

**Аяз Гыйләҗевнең тоткынлыктан язган хатлары**



**Аяз белән Нәкыянең студент туе. 1957, 27 апрель**



**«Чаян» журналы редакциясендә. Беренче рәттә (сулдан уңга): Аяз Гыйләҗев, Габделхәй Хәбиб, Галимҗан Сәгыйдуллин (драматург), икенче рәттә рәссам Петр Новичков, Шәүкәт Галиев. 1958**



**Бер төркем язучылар. Беренче рәттә (сулдан уңга): Аяз Гыйләҗев, Әнвәр Давыдов, Самат Шакир, Илдар Юзеев; икенче рәттә: Гамил Афзал, Мәҗит Рәфыйков, Шәриф Хөсәенов, Шәүкәт Галиев, Гөлшат Зәйнашева. 1962**



**Аяз Гыйләҗев (уңнан икенче), Югары әдәби курсларны тәмамлагач, курсташлары белән. Ленинград, 1963**



**Аяз Гыйләҗев гаиләсе белән.**
**Хатыны Нәкыя, уллары Искәндәр (сулда) һәм Мансур. 1965**












**«Күзгә ачы җилләрдә» (режиссёры — Габдулла Йосыпов) спектакленнән күренеш. 1961**





ТАЛОН
к почтовому переводу
На 3000
Ат кого Гилязова Аяза Миргаязовича
Адрес г. Казань, ул. Куль-Урам. д № 1. кв2

Аяз Гыйләҗев ireккә чыккач, 1962 елларда Урта Багражда эти-әнисенә салдырган йорт



Туган нигездә очрашу. 1970



**Аяз Гыйләҗев белән Якуб Зәнкиев ауда.**
**Хуҗайлан (Төмән өлкәсе). 1966**



**Аяз Гыйләҗев эш бүлмәсендә. 1970**



**Рабит Батулла, Вакыйф Нуруллин, Аяз Гыйләҗев, Әмирхан Еникиләр нәшрияттa Яхъя Халитовның (уңнан беренче) эш бүлмәсендә**



**Бер төркем сәнгать әһелләре Чаллыда «КамАЗ» төзелешендә. Сулдан уңга: Туфан Миңнуллин, Аяз Гыйләҗев, Вакыйф Нуруллин, Әмирхан Еники, Хәй Вахит. 1974**



**Кырлайда Тукай көннәре. Сулдан уңга: Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Фатих Хөсни, Илдар Юзеев. 1972**



**Аяз Гыйләҗев гаиләсе белән. 1974**



**Сулдан уңга: Аяз Гыйләҗев, Нәҗип Әсәнбаев, Туфан Миңнуллин. Кырлай, 1975**



**Аяз Гыйләҗев һәм Шәриф Хөсәенов. 1979**



**Каләмдәшләр белән. Сулдан уңга: Гәрәй Рәхим, Атилла Расих, Аяз Гыйләҗев**



**Туфан Миңнуллин белән. 1980**



**«Өч аршын җир» (режиссёры – Фаил Ибраһимов) спектакленнән соң Актаныш халык театры артистлары белән. 1980**



**А. Гыйләҗев Таҗикстанның Куляб шәһәрендә. 1983**



СССР язучыларының VII съезды. Кремль съездлар сарае, 1981



ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге тапшырылганнан соң. Аяз Гыйләҗев, Ринат Мөхәммәдиев, Мөхәммәт Мәһдиев, Туфан Миңнуллин. 1983



**Уфадан килгән иҗатташ дуслар белән. 1983**




**Чувашиядә әдәбият көннәре. 1984**



**«Җидегән чишмә» берләшмәсендә очрашуда. Түбән Кама, 1984**



**Аяз Гыйләҗев Миркасыйм Госмановның 50 яшьлек юбилее уңаеннан Казан дәүләт университетында чыгыш ясый. 1984**



**Аяз Гыйләҗев һәм Нурихан Фәттах. 1986**



**Дуслар белән. Утырганнар (сулдан уңга): Аяз Гыйләҗев, Туфан Миңнуллин; басканнар: Илшат Йомагулов, Рифкать Исрафилов, Сөендек Сәетов. 1986**



**Сулдан уңга: Мөдәррис Вәлиев, Аяз Гыйләҗев, Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев. 1986**




**Сарман районы Ләшәү Тамак мәктәбендә очрашу. 1980 еллар**



Уфа театрында кунакта. 1986



«Өч аршын җир» спектакленең премьерасыннан соң.
Аяз Гыйләҗев һәм спектакльнең режиссеры
Марсель Сәлимҗанов. 1987, 1 апрель



**«Казан утлары» журналы редакциясендә. Сулдан уңга: Хәйдәр Гайнетдинов, Рашат Низамиев, Госман Садә, Аяз Гыйләҗев, Рәдиф Гаташ. 1988**



**Татарстан язучыларының XI съездында. Сулдан уңга: Туфан Миңнуллин, КПСС Үзәк Комитеты секретаре Гомәр Усманов, Аяз Гыйләҗев, КПССның Татарстан Өлкә комитеты беренче секретаре Минтимер Шәймиев, Рахмай Хисмәтуллин. 1989**



**Балтачта әдәбият көннәре. Сулдан уңга: Мөхәммәт Мәһдиев, Ринат Мөхәммәдиев, Марат Әхмәтов (чыгыш ясый), Рөстәм Мингалим, Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Ркаил Зәйдулла, Ренат Харис. 1994**



**Каләмдәшләр белән Язучылар берлегендә. «Сарман» кафесы ачылган көн. 1990 еллар**




1988 елда Аяз Гыйләҗев Баграж чишмәсен төзекләндерә һәм истәлек тактасын куйдыра




Гыйләҗевләр гаиләсе Зәй районы Урта Баграж авылында Мирсәет һәм Мөгаттәрә яшәгән йорт каршында. 1995



Аяз Гыйләҗев Төркиядә ялда. Истанбул, 1999



**Зәй имәннәре янында. 1998**



**Кадыйм Нуруллин, Рәшат Гыйләҗев, Аяз Гыйләҗев,**
**Шамил Закиров, Искәндәр Гыйләҗев. 2001**



**Аяз Гыйләҗевнең зур гаиләсе. 2014**




**Казан федераль университетында, «Йәгез, бер дога!» роман-хатирәсенең рус теленә тәрҗемәсен тәкъдим итү кичәсе. Сулдан уңга: Разил Вәлиев, Искәндәр Гыйләҗев, Арпад Галгоци, Нәкыя Гыйләҗева, Миләүшә Хәбетдинова, Искәндәр Ярмакеев. 2016**



**165 нче мәктәпнең Аяз Гыйләҗев музеенда. Сулдан уңга: Арпад Галгоци, Миләүшә Хәбетдинова, мәктәп директоры Айдар Шәмсетдинов. Казан, 2016**




**Наил Ишмөхәммәтов, Арпад Галгоци, Фатих Кутлу, Миләүшә Хәбетдинова, Искәндәр, Нәкыя, Алсу һәм Мансур Гыйләҗевләр язучының 90 еллыгына багышланган пресс-конференциясендә. 2018**




**Гыйләҗевләр гаиләсе Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы дәүләт татар драма театрын ачу тантанасында. 2020**